Фәүзия БӘЙРӘМОВА




**Романнар**

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2005

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2Рос=Тат)–44
Б 86

**Бәйрәмова Фәүзия**

Б 86 Кырык сырт: Романнар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. — 672 б.

Язучының әлеге китабына соңгы елларда язылган яңа романнары тупланды. Аларда, аерым шәхесләрнең һәм нәселләрнең язмышы аша, милләт тормышы тасвирлана, тарихның фаҗигале яклары ачыла.

ISBN 5-298-04153-1

© Татарстан китап нәшрияты, 2005
© Бәйрәмова Ф.А., 2005



# КЫРЫК СЫРТ

Кар диңгезеннән башланып киткән Урал таулары, кыйтгаларны урталай ярып, меңнәрчә чакрым дәһшәтле юллар үтәләр дә, Ырынбур далаларына килеп җиткәндә, тәмам хәлсезләнеп, әкрен генә юкка чыгалар. Мәңгелек боз иленнән бу кайнар чүлләргә алар әйтерсең лә комга әйләнеп бетү өчен генә ашкынган. Әмма алар инде үз эшләрен эшләгән — тау-таш булып яктылык һәм караңгылык арасына баскан, көнчыгыш белән көнбатыш арасына кыя булып калыккан. Үзенекен саклау өчен, мәгърип белән мәшрикъ арасына мәңгелеккә сузылып яткан. Аның аша озак заманнар атлылар да, җәяүлеләр дә үтә алмаган. Бу тауларның төп хуҗалары татарлар гына Уралның кырыс холкын аңлаганнар, аның белән җайлашып яши алганнар...

Бик югарыдан, җиһан биеклегеннән караганда, Уралтау көньякка таба кинәт кенә чәрдәкләнеп, таралып-тармакланып китә. Әйтерсең лә күктән яшен ташы төшеп, аны шулай чәрдәкләп, чәчеп ташлаган, җир астыннан бәргән ялкын барысын өскә актарып чыгарган. Һәм бу таш-кыялар, Аурупа белән Азия кыйтгасы арасында чик сызыгы булып, мәңгелеккә катып калганнар.

Кырык сырт... Урал тауларын аркылы чыгу өчен, мәгърибтән мәшрикъка үтәр өчен, шушы кырык сыртны кичәргә кирәк булган. Кышларын үтә алмаслык кар-бураннарга батып утырган, җәйләрен тирән тау елгалары һәм төпсез сазлыклары белән сагалап торган кырык сырт. Ерткыч аю-бүреләре, барс-капланнары үкереп торган, зәһәр еланнар мыжгып яткан кырык сырт. Уралтауны белмәгән кеше аларны үтә алмаган. Тормышны белмәгән кеше аның аша чыга алмаган.

Кырык сырт... Аның Ямантау, Ирәмәл кебек кот чыгарлык зурлары һәм биекләре дә, Ирәндек кебек далага сеңеп юкка чыгучылары да бар. Бу тау сыртларыннан кырык елга бәреп чыга, аларның Агыйдел, Җаек кебек киң дәрьяга әйләнгәннәре дә, Йөрүзән, Ай һәм Уй кебек, башкаларга кушылу өчен генә юлга чыгучылары да бар. Бу суларның холкын-кәефен белмәгән кеше Урал тауларын кичеп чыга алмый. Биредә яшәүче татарларның гомер-гомергә үзләре генә белгән кичү-сукмаклары булган, кыргый җәнлекләр ар-

тыннан алар тау сыртларын кичкәннәр, су юлы буйлап диңгезләргә хәтле барып җиткәннәр. Агыйдел исә аларны Чулман-Идел белән тоташтырган. Татарларны Урал таулары кебек борынгы чорларында «Тау ирләре» дип атаганнар, аннан төшеп, алар көнчыгыштан Себер киңлекләренә, Тургай далаларына, Азиягә таралганнар, көнбатыштан Аурупага юл тотканнар...

Тау ирләре — татарлар — Урал тауларының кырык сыртын да үзләренә буйсындырганнар, үз файдаларына кулланганнар. Аның мәрмәр ташларыннан, гранит кыяларыннан кирмән-шәһәрләр салганнар, тимер һәм бакырыннан корал һәм кирәк-ярак ясаганнар, алтын-көмешен, зөбәрҗәт-фирүзәләрен матурлык өчен кулланганнар... Уралтауның кырык сырты кырык гасыр буе татарларга хезмәт иткән...

Аннан Урал татар кулыннан киткән, андагы байлыкка кызыгып, бу якларга кыргый һәм явыз кавемнәр килеп тулган. Урал белән бергә Себер киткән, Тургай далалары, Идел-Җаек киткән. Чит кавем, саранча явы кебек, барысын да басып алган. Алар горур тау ирләренең ил-җирләрен тартып алганнар, телләрен, тарихларын, диннәрен җимергәннәр, кол булып үзләренә эшләргә мәҗбүр иткәннәр. Татарлар бу явыз яэҗүҗ-мәэҗүҗ кавеме өчен тау актарганнар, тимер чыгарганнар, корал ясаганнар, шәһәрләр төзегәннәр, җир сөргәннәр, икмәк үстергәннәр.

Аларга яңадан, үз ил-җирләрен кире кайтару өчен, телләрен һәм диннәрен, хакыйкатьне торгызу өчен, тарихның кырык сыртын янә үтәргә кирәк була. Әмма бу кырык сыртны кичү серләрен инде бик азлар гына белә булып чыга. Һәм бик азлар гына, Уралтауның кырык сыртын исән-имин кичеп, тормыш дәрьясының аргы ягына чыга ала. Морза Мирзаяннар нәселеннән булган Асылгәрәй карт, Урал тауларының гына түгел, язмышының да кырык сыртын исән-имин кичеп, нәселенә телне, динне, татар тарихын әманәт итеп биреп калдыра.

Бу кыйссабыз тарихның кырык сыртын кичкән татар ире Асылгәрәй турында...

Һәй... Һәй... Һәй...
Урал тауларында кырык сырт.
Урал тауларына үпкәләмим,
Язмышкайларымда кырык сырт...

Һәй... Һәй... Һәй...
Урал тауларында кырык сырт.
Урал тауларына үпкәләмим,
Татар тарихында кырык сырт...
Һәй... Һәй...Һәй...

* * *

Зәй елгасының югары агымына утырган бу татар авылын халык телендә Зәйтуган дип йөртәләр. Рәсми кәгазьләрдә ул төрле вакытта төрлечә язылган, әмма халык барыбер үзенчә — Зәйтуган дип атап йөрткән. Авыл бик зур булып, аның бик борынгыдан килгән үз тарихы, үз тәртип-кагыйдәләре бар. Зәйтуган бигрәк тә үзенең затлы нәселләре, гыйлем кешеләре һәм искиткеч бай, матур табигате белән аерылып тора. Хәер, бөтен яктан да килгән мондый гүзәллектә бары тик гүзәл кешеләр генә яшәргә тиеш кебек. Әмма монда да төрлесе бар... Кырык буын шәехләр нәселенә барып тоташа торган хикмәт ияләре дә, сәнәктән көрәк булган надан ертлачлар да яши Зәйтуганда. Бигрәк тә Октябрь инкыйлабы барысын да бутап ташлады, акыл ияләрен аяк астына салып таптады, затсызларны өскә күтәрде... Барысы өчен дә уртак булып хәзергә тел һәм табигать кенә калды...

Ә табигать Зәйтуганда әкияти матурлыкка ия...

Урал тауларының иң соңгы сулышы булып авыл тирәли сөзәк таулар тезелеп киткән. Алар Зәйтуганны котып яктан искән салкын җилләрдән саклап торалар кебек. Тауларның һәрберсенә халык үзенчә исем биргән. Очлытау — шуларның иң биеге. Заманында аннан бакыр чыгарганнар, аннан соң бу тирәләрдән җир мае сыгарлар... Алыптауда исә тимер чыккан, халык аннан сугыш кораллары ясаган. Беләүлетаудан исә таш чыгарганнар, Зәйтугандагы күп корылмалар шул таштан салынган. Әнә, бер-берләренә тоташып, Бөркет һәм Туктартау, Ташкеләт һәм Җәйләү, Кырык чишмә таулары, Каратай сыртлары тезелеп киткән. Шунда ук халык печән әзерли, мал йөртә торган Баязит һәм Якуп тарлаулары.

Таулар беткән җирдә таллар башлана, тоташ әрәмәләр, урманнар китә, сазлыклар җәелеп ята. Әнә Акман кичүе әрәмәсе, күкерт чишмәле Күкертле әрәмәсе, Аит сазлыгы, Даулы аклан, Олы саз урманнары, Җирти каенлыгы, Тамбикә чишмәсе, Әтәч, Зәй елгалары. Һәрберсе татарча исемнәре белән җырлап тора... Зәйтуган халкы гомер буе шушы урман-әрәмәләр, елга-таулар белән көн күргән, барысын да шулардан алган, шуңа рәхмәтле булып яшәгән... Татар халкы заманында ил-дәүләтен югалтса да, ул әле җирен җуймаган, тау араларында, урман эчләрендә, авыл-авыл булып, үзенчә яшәп ята... Әмма Октябрь инкыйлабы бу авылларның гына түгел, табигатьнең дә астын өскә китереп ташлый... Яңа хакимияткә җир җитми — Зәйтуганның әкияти урманнарын кисеп, бөдрә әрәмәләрен киптереп, иген чәчтерәләр, тарлауларга колхоз малын кертеп тутыралар. Советларга байлык җитми —

татарның җәннәттәй җирләрен актарып, Зәйтуган болыннарыннан, тау итәкләреннән нефть чыгара башлыйлар, авыл тирәсенә шуны эшкәртә торган заводлар салып куялар. Зәйтуган өстен кара сөрем баса, аңа ияреп, авылга зәхмәт чире үтеп керә...

Зәйтуган, Зәйтуган...

Җырларда җырланган, тарихи дастаннарга кергән данлыклы Зәйтуган...

Бу тирәдәге татар авылларының ул, мөгаен, иң борынгысыдыр... Аның зиратыннан хәтта меңьеллык кабер ташлары да табылган. Авылда бик борынгыдан килгән затлы нәселләр шактый, шуларның иң билгелесе — Морза Мирзаяннар нәселе. Зәйтуган зиратында табылган кабер ташын Асылгәрәй хәзрәтнең борынгы бабасы Җанбулат морзаныкы булырга тиеш, диләр. Димәк, кимендә кырык буын имам һәм мөдәррисләр, шәех һәм хаҗилар нәселеннән ул Морза Мирзаяннар. Октябрь инкыйлабы башланганда, авылда Асылгәрәй хәзрәт имамлык итә. Һәм утызынчы елларның сөрелү фаҗигасен дә ул мулла буларак каршылый...

Асылгәрәй хәзрәт үзе дә, Төркиядә укыганда, дүрт тапкыр хаҗ кыла, моннан тыш күп гарәп илләрендә була, белемен Мисырда дәвам итә, гомер буе гыйлем туплый, дөньяны өйрәнә. Ул шул илләрдә яшәп тә кала ала иде, зур гыйлеме, күркәм холкы сәбәпле, аңа һәркайда ишек ачык булды. Әмма ул туган иленә, ата-баба нигезенә, Зәйтуганга кайтып төпләнде. Шактый олыгаеп булса да өйләнде, гаилә корып җибәрде, Зәйтуганда тормыш итә башлады. Хатыны да үзенә тиң булып чыкты, ул заманы өчен шактый укымышлы, алдынгы карашлы кеше, Колшәриф авылы мулласының төпчек кызы Маһинур иде...

Аларның авылдагы тормышлары башта ук кешенекеннән шактый аерылып торды, бик үзенчәлекле иде. Инде ярты дөньяны гизгән, күп нәрсәләр күргән, затлы шәһәрләрдә зур белем алган Асылгәрәй хәзрәт Зәйтуганга да замана сулышын, шул яңалыкларны кертергә тырышты. Шөкер, хатыны да аны аңлый торган, яңалыкка, матурлыкка омтыла торган киң күңелле гаять уңган кеше булып чыкты. Аларның яңача, затлы-мәгърифәтле тормышта яшәргә тырышулары бөтен эшләрендә чагыла иде. Үз-үзләрен тотышларында да, йорт төзелешләрендә дә, мәчет эшләрендә дә. Яшь хәзрәт, Зәйтуган мәчетендә имам булу өстенә, авылның атаклы мәдрәсәсен дә тота, ә Маһинур абыстай өендә кыз балалар укыта иде. Асылгәрәй хәзрәт авыл халкына дин өйрәтүне дә яңарак алымнар белән алып барырга тырышты. Ул, гомумән, ислам динен куркыту юлы белән аңлатуга каршы иде, яшь мулла Коръәнне фәндәге яңа ачышларга нигезләп тө-

шендерергә омтылды. Шуңа күрә ул мәдрәсәдә шәкертләргә җәгърафия, күк фәне, дөнья тарихы кебек дәресләр дә бирә башлады, чөнки ул үзе дә Төркиядә һәм Мисырда шул рәвешле укыган иде. Әлбәттә, аның дәртләнеп сөйләгәннәрен авыл халкының аңлаганы аңлады, аңламаганы юк, әмма аңа читтән шәкертләр күп килә иде. Белгәннәрен Зәйтуган кысаларында гына калдырмас өчен, Асылгәрәй хәзрәт дин һәм тарих буенча берничә китапчык та язып, аны Казанда бастырып чыгара алды. Андагы зур гыйлем, шул гыйлемне дөрес һәм үтемле итеп аңлатып бирә белү Казан галимнәрен дә гаҗәпләндерде, алар дин һәм фән өлкәсендә яңа йолдыз туып килүен күреп сөенделәр. Әмма Октябрь инкыйлабы боларның барысын да чәлпәрәмә китереп ташлады. Яңа властька татарның фәне дә, дине дә кирәк түгел иде, аларга бары тик аның байлыгы һәм хезмәте генә кирәк иде...

Асылгәрәй хәзрәт белән Маһинур абыстайның яшәү рәвеше дә барысыннан да аерылып тора иде. Яшь хәзрәт үзенә йортны төрекләр һәм мисырлылар үрнәгендә, ике катлы итеп, бер өлешен таштан салдырды, ягъни аскы каты — Беләүлетау ташыннан, өске каты Акман урманы наратыннан иде. Өстә хәзрәтнең ишле гаиләсе яшәсә, аста Маһинур абыстай гомер буе Зәйтуганның кыз балаларын укытты, кием текте, балаларын кул һөнәренә өйрәтте. Аның кызлары тегә дә, чигә дә, тукый да беләләр иде. Ә малайлар исә яшьтән әтиләренең кул арасына кереп үстеләр, зур хуҗалыкта әтиләренең төп ярдәмчеләре булдылар. Асылгәрәй хәзрәтнең хуҗалыгы, бигрәк тә җимеш бакчалары, авылга гына түгел, бөтен тирә-якка дан иде. Читтә күргән үрнәк белән ул Зәйтуганда беренче булып зур җимеш бакчасы булдырды, моның өчен бакчасының яртысын бүлеп алды. Аның бакчасында алмахөрмәдән алып йөземгә хәтле үсә иде. Мондый затлы җимешләрне Казан базарларында гына күргән авыл халкы өчен бу бакча чын мәгънәсендә могҗиза иде. Асылгәрәй хәзрәт үзе белгәнне башкаларга да өйрәтте, авылдашларын, ит белән бәрәңгедән тыш, җиләк-җимешкә дә ияләндерергә тырышты. Алардан күреп, күпләр өй артларына җәннәт җимешләре утырта башладылар...

Карарга күп вакытны алса да, Асылгәрәй карт умарта да тотты, аларның саны кырык-иллегә хәтле җиткән вакытлары бар иде. Чөнки балалы йортта төп дәва булып бал һәм үләннәр тора, һәм бөтен авыл халкы, авыргач, аларга килә иде. Тора-бара бу нечкә эшкә Маһинур абыстай һәм олырак балалар да өйрәнде. Инде кул арасына балалар да керә башлагач, бәрәңге бакчасының тагы бер өлешен бүлеп алып, төтәл-түтәл яшелчә үстерә башладылар, шулай итеп, Зәйтуган тарихында беренче булып авылга кыяр һәм помидор, кәбес-

тә һәм кишер керттеләр, халыкны суган-сарымсакка өйрәттеләр...

Әмма авыл халкын, бигрәк тә хатын-кызларны иң нык гаҗәпләндергәне: Асылгәрәй хәзрәтнең шау чәчәктә утырган ишегалды иде. Алар анда мал-туар кертмиләр, хайваннар бөтенләй башка юлдан, башка капкадан йөри, йорттан читтәрәк бакча башында яши иде. Шуңа күрә җәй буе хәзрәтнең ишегалдында ямь-яшел чирәм үсеп утыра, гөлләр чәчәк ата. Матурлыкны кайда да яраталар шул, җәй буе халык бирегә могҗиза карарга килгән кебек җыела, бигрәк тә — балалар һәм хатын-кызлар. Ә гөл-чәчәкләрнең ниндиләре генә юк монда — елга бер чәчәк ата торган чәнечкеле кактус дигәннәре дә, кып-кызыл роза гөлләре, ап-ак кашкарыйлар, тагы адәм баласы исемнәрен дә белмәгән әллә нинди гөлчәчәкләр. Хәзрәт аларның орлыкларын бөтен дөнья буйлап җыя икән, кайда барса, шуннан гөл орлыгы алып кайта, хатыны Маһинур абыстай башта аларны өйдә чүлмәктә үстереп карый, тамыр җибәргәч, ишегалдына алып чыгып утырта. Кызлары үсеп, кул арасына керә башлагач, бу гөл-чәчкәләрне карау тулысынча алар өстендә калды. Асылгәрәй хәзрәт белән Маһинур абыстайның тугыз баласы менә шушы гөлләр арасында үзләре дә, чәчәк кебек булып, бик бәхетле үстеләр. Октябрь инкыйлабы исә бу гөл оясын туздырып, барысын да астын өскә китереп ташлады...

Хәер, инкыйлабтан соң да әле хәзрәт тиз генә бирешмәде, гаиләсен, балаларын, йорт-җирен ул елларның канлы афәтеннән саклап кала алды. Гаилә советлар сугышыннан да, ачлыктан да исән-имин котыла алды, Әлмәт якларын ду китергән сәнәк сугышы да аны аяды, кагылмады. Чөнки Асылгәрәй хәзрәт бу яклар өчен бик билгеле, дәрәҗәле кеше иде, шуңа күрә аклар да, кызыллар да аңа кагылырга батырчылык итмәделәр. Әмма дөньялар инде тыныч түгел иде, илне, авылны хәерчелек басты, кешеләр явызланганнан-явызлана бардылар, дин онытылды, муллаларның сүзе кирәксезгә чыга башлады. Дөнья сулышын бик яхшы тойган, Казаннан гына түгел, Мәскәүләрдән дә газета-журналлар яздырып алып яткан Асылгәрәй хәзрәт эшләрнең кая таба барганын яхшы аңлый иде. Диннән, дөреслектән ваз кичкән бу илнең кайчан да булса бер дөбердәп җимерелеп төшәсен ул белә иде. Үз нәселенең, үз гаиләсенең дә шушы җимерекләр астында калырга мөмкинлеген хәзрәт чамалый иде, әмма ул үз теләге белән Зәйтуганнан кубарылып чыгып китә алмады. Югыйсә баштагырак елларда Төркиягә дә, Мисырга да барып урнашу җае бар иде. Туган авылын, гөлләргә күмелеп утырган нигезен, милләтен ташлап китә алмады ул. Балаларын илдән аерасы килмәде. Әмма бу яңа хакимиятнең ни дәрә-

җәдә явызлыгын, кешелексезлеген ул да аңлап бетермәгән икән…

Утызынчы елларның хәвефле көннәрен ул үз авылында, үз нигезендә тугыз баласы белән бергә каршылады. Дөрес, Сабирасы белән Равиленең инде үз гаиләләре бар иде, ә калганнары бары да әти-әнисе кулына карап торалар. Бары тик өй тәрбиясе алган, Коръәнне, динне яхшы белгән әдәпле, әхлаклы балалар. Гөлләр арасында туып, чәчәк кебек үскән сабыйлар… Иң төпчекләре — Мәрзия белән Рәйсә, алар игезәкләр, әле ун яшьләре дә тулмаган… Солтанхәкимгә исә унбер яшь… Бу вакыйгалар башланганда, Саҗидәгә унөч, Сәгыйтькә унбиш, Гыйлемгәрәйгә уналты, Гайшәбикәгә унсигез яшь иде… Һәм шушы җиде баласын ияртеп, Асылгәрәй карт белән Маһинур абыстай авылдан чыгып китәргә тиешләр иде… Юк, Зәйтуганнан куылырга, сөрелергә тиешләр иде. Урал тауларының аръягына, ач далага, тәмуг базына. Яңадан илгә кайту өчен, ул Урал тауларының кырык сыртын җәяүләп үтәргә, язмышының кырык сыртын кичәргә тиеш иде…

* * *

Зәйтуган Урал тауларының иң соңгы тезмәләрендәге калкулыкларга урнашкан. Чын кыя-тауларга хәтле әле бередән ара бик ерак, аның өчен мең чакрымга якын юл үтәргә кирәк. Урал аръягы исә бередән тагы да ерак, аның көньяк-көнчыгышында җәелеп яткан ач далаларга Зәйтуган халкын куып та җибәреп булмас иде. Дөрес, әле теге заманнарда ук, Октябрь инкыйлабына кадәр, Зәйтуганнан Рәми бабайлар нәселе ул якларда алтын базлары тоткан, ул җирләрнең хуҗасы булган. Әмма алар үзләре дә анда барып-кайтып кына йөргәннәр, яшәүләре барыбер заманча шәһәрләрдә, яллары яшел җәйләүләрдә үткән… Октябрь инкыйлабы барысының да астын өскә китереп ташлаган…

Рәмиевләрдән талап алган алтын беткәч, татар һәм урыс байларыннан калган мал җилгә очкач, яңа хакимият алдына яңа бурычлар килеп баса… Алга таба ничек яшәргә, инде кемне таларга? Шәһәрләр ач, илдә тәртип юк, бөтенесе хәрабәләр эчендә ята… Таланып бетмәгән ике нәрсә калган — авыл һәм табигать. Ул елларда сатып көн күрерлек бердәнбер нәрсә — тимер һәм күмер. Һәм яңа хакимият теше-тырнагы белән шуларгаябыша. Урал тауларында, Магниткада, Донбасста һәм Кузбасста тиңе булмаган зур төзелешләр башланып китә. КПСС һәм СССР хөкүмәте илне индустрияләштерү турында карар арты карар кабул итә, әмма эш бармый. Кемнәр белән күтәрергә бу төзелешләрне, ач халыкны

ничек мәҗбүр итәргә анда көне-төне эшләргә? Шәһәр халкы анда бармый, комсомол-активистлар адәм чыдамаслык бу шартлардан кача. Гигант төзелешләрне туктатмас өчен, бары тик бер генә юл кала — авыл халкын анда эшләргә мәҗбүр итәргә. Үз теләкләре белән анда бармыйлар икән, суд юлы белән бәйләп куярга...

Һәм 1930 елны кулакларны сыйныф буларак юк итү турында хөкүмәт карары басылып чыга. Кулак тамгасы сугып, авыллардан хәллерәк кешеләрне, дин әһелләрен, укымышлы халыкны, сәүдәгәрләрне куу башлана. Халыкны куркыту өчен, аларның бер өлешен шунда ук атып үтерәләр, күпчелеген гаиләләре белән бергә сөргенгә сөрәләр... Татар муллаларын Арханьгельск урманнарын кисәргә җибәрәләр, эшләрдәй хәлле кешеләрне Урал аръягына, Магнитка төзелешенә сөрәләр... Магнитка шәһәрен һәм металлургия комбинатын төзү еллары нәкъ кулакларны сөрү чорына туры килә. Шулай итеп, авыл халкын суд юлы белән шушы бөек төзелешләргә мәңгелеккә бәйләп куялар. Ил берьюлы ике мәсьәләне — гигант төзелешләр һәм эшче коллар мәсьәләсен хәл итә. Урал аръягындагы Магниткада бу эшче колларның күпчелеге авыллардан сөрелгән татарлар була.

Асылгәрәй хәзрәтнең асыл нәселе дә шушы канлы тегермән астына барып керә...

Башта барысы да күмәкләштерүдән башлана...

Гомер буе үз җаена яшәргә өйрәнгән Зәйтуган халкы һич кенә дә күмәк хуҗалык төзергә теләми. Халыкны бушлай ашату белән дә, балалар өчен бушлай бакчалар белән дә кызыктырып карыйлар — беркем уртак тормышка риза булмый. Халыкны бигрәк тә бу эшләрнең башында Шайтан Шакир кебек әтрәк-әләмнәрнең торуы гайрәтен чигерә, үз исемен дә яза белмәгән затсыз бер хәерченең яңа тормыш төзибез, дип, кеше котыртып йөрүеннән көләләр генә. Әмма соңыннан күпләргә моның өчен кычкырып еларга туры килә...

Башта ирекле дип башланган колхоз соңга таба мәҗбүр итү төсмерен ала. Колхозга кермәгән кешеләргә зур-зур салымнар китереп салалар, аларның соңгы икмәкләрен, малтуарларын, каз-үрдәкләрен җыеп алып чыгып китәләр. Халык, бу көчләүләргә түзә алмыйча, уртак малга ут төртүләргә хәтле барып җитә, авыл халкы белән яңа хакимият арасында чын мәгънәсендә игълан ителмәгән сугыш башланып китә. Район үзәкләреннән — Әлмәттән, Шөгердән, Бөгелмәдән — һәр көн татар авылларына «штурмовые бригады» дип аталган җәза төркемнәре чыгып китә, халыкның соңгысын кычкыртып талау башлана. Һәм беркөнне җәза отряды Зәйтуганга да бәреп керә. Аларга авылның куштаннары, ком-

сомол һәм коммунистлары да кушыла... Югарыдан килгән әмер буенча, өч көн эчендә Зәйтуганда колхоз төзелергә, кешеләрнең мал-мөлкәте җыеп алынып, уртак казнага салынырга тиеш була. Моның белән ризалашмаганнарны урында ук җәзага тартырга рөхсәт ителә...

Бөгелмәдән килгән урыс талаучыларының тирәсендә, исемлек тотып, Шайтан Шакир бөтерелә. Шаһгали кебек котсыз кыяфәтле, ямьсез һәм гарип рәвешле бу бәндә авылда коммун төзүдә башлап йөри. Юньләп укый-яза белмәсә дә, ул Бөгелмә урысларына кем, нәрсә кирәген яхшы белә, аларны туп-туры байлар өстенә алып китә. Менә ул, наганнарын шалтыратып, аларны Асылгәрәй картларга алып бара, чөнки бу морзалар нәселе белән аның үз исәп-хисабы бар... Теге елларда хезмәтче итеп тотканнары өчен генә түгел, узган кыш бөтен авыл алдында хурлыкка калдырулары өчен дә мәңге үчле аларга Шайтан Шакир... Шуның өчен ул аларның бөтен нәселләрен корытачак әле...

Ә эш болай була...

Хәзрәтнең олы улы Равил Зәйтуганның иң чибәр, иң үткен кызын — Вәсимәне яратып йөри. Кыз да аны ярата, егет Бөгелмәдә курсларда укып бетерүгә, өйләнешергә уйлап торалар иде. Яңа власть сәбәпле авылда иң зур хуҗа булып алган Шайтан Шакир да кызга кызыгып йөри икән. Кулындагы властьтан файдаланып, кызның әти-әнисен кайда куркытып, кайда сатып алып, ул Вәсимәне, көчләп диярлек, үзе белән язылышырга мәҗбүр итә. Әмма үткен кыз, язылышу бетү белән, Шайтан Шакир ирләр белән тәмәке тартып торган арада, авыл советыннан чыгып кача... Ул алдан ук Равил белән килешкән була, һәм егет, аны алып, атка утыртып, кыз белән Зәйтуганнан чыгып кача. Шайтан Шакир аларның артларыннан куа чыкса да, яшьләр, авылдан авылга качып, Бөгелмәгә хәтле барып җитәләр, никах укытып, бергә яши башлыйлар. Шул китүдән алар авылга кайтмыйлар, Бөгелмәдә яшәп калалар. Шулай итеп, үзенең кемлеген белмичә, чәчәктәй кызга үрелгән, яраткан ярлар арасына кергән Шайтан Шакир тагы адәм көлкесенә кала, халык теленә менә.

Шайтан Шакирның өйгә шулай кинәт кенә бәреп керүенә Асылгәрәй хәзрәт аптырап калды, аны әле болай беркемнең дә басымчак иткәне юк иде. Ул бөтен салымнарын да вакытында түләп бара, бу власть белән бернинди алыш-биреше, низагы юк. Ул арада Шайтан Шакир талау төркеменә умарталарны төяргә кушты, абзардан сарык-сыерларны ачып чыгарды. Боларына инде Асылгәрәй хәзрәт түзмәде, юлларына аркылы төште.

— Бу ниткән көпә-көндез кеше талау? — диде ул урысча-татарчалап. — Мин барлык салымнарымны түләп барам, яңа

власть алдында бернинди дә гаебем юк. Нигә дип сез минем мал-мөлкәтемә тиясез?

— Ә нигә калхузга кермисең?! — дип чәчрәп, аңа каршы чыкты Шайтан Шакир. — Башкаларны да аңа каршы котыртып ятасың? Калхузга керсәң, умарталарың да, мал-туарың да яңадан үзеңнеке булачак. Юк икән юк инде, мулла абзый, хезмәт халкы файдаланачак алардан. Сезнең болай да симерүегез җиткән. Кеше аермаган тәреләр...

Хәзрәт аңлап җитмәсә дә, Маһинур абыстай сизенеп алды — Равил белән Вәсимәнең никахына төрттерә иде Шайтан Шакир. Ахрысы, форсаттан файдаланып, шуның өчен дә үч ала иде...

Бераз салып алган урыслар, мулла белән абыстайның айваена карамастан, өйдән бар нәрсәне төяп алып чыгып киттеләр. Шайтан Шакир кайда нәрсә ятканын яхшы белә, әле теге елларда ул хәзрәтләрдә хезмәтче малай булып йөргән иде. Дөресен әйткәндә, кызганып, ул вакытта алар аны үзләре эшкә чакырдылар, хезмәте өчен ризыгын да, өс-башын да мулдан бирделәр. Шайтан Шакирның әтисе авылда бердәнбер эчкече иде, эчкән баштан хатынын кыйнап үтерде. Өй тулы ятим балалар ачтан үлмәсен өчен, Асылгәрәй хәзрәт бу малайны кул арасына эшкә алган иде... Ә ул гомер буе рәхмәт урынына, эчендә ачу, үч асраган икән. Җае чыгу белән шуларны чыгарды менә...

Шулай итеп, хәзрәтнең үз атларын җигеп, шуңа умарталарны, сарык малларын төяп, сыерларны чана артына тагып, җәйгән урыннан түшәк-ястыкларга хәтле сыдырып алып, талаучылар төркеме югары очка менеп китте. Авыл өстендә кычкырыш, елаш, каргыш, янау тавышлары эленеп торды, шарт-шорт аткан тавышлар ишетелде. Өй саен кереп тентүләр, янау, кыйнаулар башланды. Алар, халыкның бугазына басып, икмәк таләп итәләр, ә халык аны инде күздән үк аларга тапшырып бетергән. Икмәге булмаган кешеләрнең малтуарларын алып чыгып китәләр, колхозга каршы котки таратуда гаепләп, кыйнап ташлыйлар, исерек баштан ни эшләгәннәрен дә белмиләр. Бу хәтле ерткычлыкны гражданнар сугышы чорында да күрмәгән Зәйтуган халкы шашып кала, мәчеткә киңәшкә җыелалар...

Монда һәркем үзенекен сөйли, үз кайгысы белән уртаклаша...

Икенче мәхәллә мулласы Садыйк хәзрәтне берьялгызын өенә бикләп куйганнар, хатынын, атка атланып, авыл советына килергә мәҗбүр иткәннәр. Кем Садыйк хәзрәткә ашарга кертә яки өендә мичен яга — шуны тотып атачаклар икән. Кемнәрдер күргән — Садыйк хәзрәтнең хатынын идарәдә бик каты кыйнаганнар, «Син совет властен таныйсыңмы?» —

дип, урысчалап сорау алганнар. Абыстай аңламагач, аны исерек урыслар алдында «Камаринский» биергә мәҗбүр иткәннәр, аннан аягыннан асып куйганнар. Кемдер кыйнаганда тәненнән өзелеп чыккан ит кисәкләрен күрсәтә, кемдер тырнак асларына энә кертеп җәберләүләре турында әрнеп сөйли. Барысына да колхозга керергә кушканнар, кермәгән очракта төрмә белән куркытканнар...

— Болай булмый, җәмагать, — диде Асылгәрәй хәзрәт, аларны тыңлап бетергәч. — Бернинди власть та кешене болай җәберләргә кушмас. Колхозга керү дә көчләп булырга тиеш түгел, мин үзем Сталинның шул хакта мәкаләсен укыдым. Бу Бөгелмә урыслары Шайтан Шакир котыртуы буенча йөриләр булыр. Делегация төзеп, яннарына барырга кирәк, кешеләрне алай җәберләмәсеннәр.

Әле генә аннан кыйналып кайтучылар яңадан авыл советына барырга теләмәделәр, күпләр, гаиләләрен алып, Зәйтуганнан качып торырга булды. Асылгәрәй хәзрәт, берничә картны ияртеп, Садыйк муллаларга китте, бикле ишекне җимереп, салкын өйгә килеп керде. Кулы-аягы бәйләп ташланган Садыйк карт суыктан һәм ачлыктан инде аңсыз ята иде. Чанага салып, аны Асылгәрәй хәзрәтләргә кайтарып куйдылар, Маһинур абыстай аны карый калды, ирләр, җыелып, идарәгә чыгып киттеләр.

Авыл советында күмәк хуҗалыкка кодалау дәвам итә иде...

Кемнедер акыртып кыйныйлар, кемнедер идән астына тибеп төшерәләр, кемнедер аяк-кулларыннан асып куеп газаплыйлар. Җәза отрядының бер өлеше шулай котырынса, икенче өлеше авыл буйлап кеше талап йөри, колхоз төзи. Асылгәрәй карт аларга бу эшләренең дөрес түгеллеген әйтеп карады, чөнки Сталин мәкаләсендә дә колхозга көчләп кертергә кушылмаган иде. Сталин исемен ишеткәч, җәза отряды бераз тынып калса да, инде канлы тегермән җибәрелгән, хәзер итәк-җиңнәрне җыярга кирәк иде. Халыкның үзен гаепләп калдырырлык мәкер уйлап табарга кирәк иде...

Асылгәрәй хәзрәт, авыл картларын җыеп, яңадан мәчеткә китте, бу вәхшилекне бераз булса да туктатып тора алуына куанып, намазга утырды. Шул чакта урам ягыннан шартшорт аткан, кычкырган тавышлар ишетелә башлады, Зәйтуган төрле баштан дөрләп янып килә иде... Мәчетне исә җәза отряды чорнап алган, алар Асылгәрәй картны советка каршы диверсия оештыруда, халыкны колхозларга каршы котыртуда гаеплиләр иде. Авыл башында кабынып киткән янгыннарны да аңа сылтап, хәзрәтне таш төрмәгә илтеп тыгарга җыеналар иде...

Бу хәлләрне белгәч, мәчет янына авыл халкы җыела башлады...

Тыкрыкларда балта-сәнәк тоткан ирләр күренде...

Мәчеттән исә, тәкбир әйтеп, картлар чыгып басты, аларга авыл халкы кушылды, Зәйтуган өстенә үзәк өзгеч шомлы моң таралды. Бер якка баштанаяк коралланган атлы урыслар тезелеп басты, икенче якта, мәчет янындагы ак кар өстенә, Зәйтуган халкы тезелде. Халык, мәсхәрәләнеп кыйналып үлгәнче, дин юлында шәһит китәргә әзерләнде. Ул арада Бөгелмә ягындагы юлдан чаптырып атлар килгәнлеге күренде, җәза отрядына ярдәмгә ашыга иде алар. Моны күргәч, алар тагы да батыраеп киттеләр, баш күтәргән халыкны мәчеткә таба кысрыклый башладылар. Халык, тәкбир әйтеп, артка чигенде, мәчеткә кереп бикләнде. Җәза төркеменнән берничә кеше мәче тизлегендә мәчет манарасына менеп китте, аның нигезенә балта белән чаба башлады. Бу хәлне күреп, урамда калган хатын-кызлар кычкырып еларга тотынды, картлар эчтә тәкбир әйтте, Аллага ялварды. Шайтан Шакир исә, форсаттан файдаланып, мәчет түбәсенә кызыл байрак элеп маташа иде.

Шулчак көтелмәгән хәл булды...

Кемдер әллә урам яктан, әллә эчтән мәчет манарасын кисүчеләргә гөрселдәтеп атып җибәрде. Манарага менеп атланган урыслар ак кар өстенә тәгәрәп барып төштеләр. Шайтан Шакир, байрагын тотып, карга сикерде, чөнки баш кадерлерәк иде. Моны күреп, калганнары да айнып киткән кебек булдылар, мылтыкларын терәп, атучыны эзли башладылар. Ул арада урамдагы хатын-кызлар кайсы кая качып беткән, ир-атлар исә мәчет эченә ныклап бикләнгәннәр иде. Өч көн буе аларга ишекне ачтыра алмадылар, Бөгелмәдән һәм Казаннан бу эшләр буенча зур түрәләр килгәч кенә, Асылгәрәй карт, үзе чыгып, барысын да аңлатып бирде. Җәза төркеменең ничә кешене кыйнаганнарын һәм үтергәннәрен, бу хәлләргә түзә алмыйча, акылдан язучылар булуын, күпме малмөлкәтне талауларын ул бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Эш зурга китте, талаучыларны да, Шайтан Шакирны да Бөгелмәгә җыеп алып киттеләр, төнлә килеп, Асылгәрәй картны да алдылар. Шайтан Шакирга һәм талаучыларга берни булмады, ә Асылгәрәй хәзрәтне Бөгелмә төрмәсенә ябып куйдылар...

Зәйтуган авылы буенча төзелгән кара исемлектә ул беренче булып тора иде. Дин әһеле, мулла булганы өчен дә, хәлле, бай тормышта яшәгәне өчен дә, чит илләрдә укыганы өчен дә, Зәйтуганда булган шушы фетнә-чуалышлар өчен дә Асылгәрәй хәзрәт җавап тотарга тиеш иде. Хәтта җәзачыларга атуны да аның нәселеннән, аның балаларыннан шикләнделәр, тик кем атканын барыбер таба алмадылар. Шайтан Шакир бу эшне бик тә хәзрәтнең олы улы Равилгә сыларга тырышты, чөнки аны ул көнне авылда күргән булганнар. Әмма моны исбатлый алмадылар, Равил исә, хатыны

Вәсимәне алып, Бөгелмәдән чыгып ук китте. Шул китүдән аны бу якларда башка күрмәделәр, соңрак Ташкент якларына барып урнашкан дигән хәбәре генә ишетелде...

Мәһинур абыстай, җиде баласын кочаклап, таланган өйдә утырып калды...

* * *

Хәзрәт кулга алыну белән, Мәһинур абыстайны, балалары белән бергә, өеннән дә куып чыгардылар. Коммунист-комсомол булып алган авыл наданнары аңа бернәрсә алырга ирек бирмәделәр, балалары аягындагы киез итекләргә хәтле «совет балаларына кирәк булачак» дип салдырып алдылар. Яңа төзелгән колхозга идарә йорты кирәк иде, талаучылар төркеме шунда кереп утырды, авыл советын да шунда ясадылар. Мәһинур абыстай исә, бер кат өс-баш белән, яшәргә мунчага чыкты. Балаларын ачка үтермәс өчен, көне-төне кешегә кием тегә башлады. Беркөнне исә авыл куштаннары, комсомоллар алар яшәгән мунчаның да түбәсен сүтеп алып киттеләр, Мәһинур абыстай балалары белән урамда торып калды. Кызы Сабира, ире Гарифны ялынып күндереп, әнисен һәм туганнарын үзләренең читән өйләренә алып кайтты. Бу эш өчен аның үзен дә өеннән куып чыгарырга мөмкиннәр иде...

Бер Мәһинур абыстай өчен генә түгел, Зәйтуган өчен, Әлмәт-Шөгер төбәге өчен кара көннәр башланды. Халыкны көчләп куып кертеп, күмәк хуҗалыклар төзесәләр дә, бер җирдә дә эш бармый, кешеләрдән тартып алган маллар ачтан үлә, иген орлыклары череп, күксеп ята иде. Монда тагы хәлле кешеләрне советка каршы коткыда гаепли башладылар, тагы кыйнаулар, кулга алулар китте. Теләсә нинди сәбәп белән бу кешеләрне туган җирләреннән сөрергә кирәк иде, чөнки зур төзелешләргә эшләргә кеше кирәк. Зәйтуганның да байтак татарларын, муллаларын, укымышлы ир-атларын, җыеп, Бөгелмә төрмәсенә илтеп ташладылар. Аларның гаиләләренә авылда көн калмады. Шушындый ук хәл янәшәдәге Габдрахман, Карабаш, Сөләй, Керкәле, Кәшер һәм башка авылларда бара иде. Татарстаннан йөз мең кеше сөргенгә сөрелергә тиеш, һәм шуның күпчелеге Кама аръягыннан, Әлмәт-Шөгер тирәләреннән иде. Гомер-гомергә хәлле, укымышлы, дини булган бу ак якларны совет власте үзенчә сындырып «тәрбияләргә», иманнан яздырырга тели иде. Асылгәрәй хәзрәт кебек ил картлары бу кара исемлекнең башында торалар иде.

Шушы бер ел эчендә Зәйтуган да танымаслык булып үзгәрде...

Кая китте кешеләрдәге мәрхәмәт, кызгану, рәнҗештән курку? Кайдан килеп керде татар авылына бер-береңне сату,

талау, мыскыллау? Ирләре Бөгелмә төрмәсендә хөкем көтеп яткан кешеләрнең гаиләләрен эт типкесендә йөртә башладылар. Өйләреннән куып чыгаргач, аларны бер җиргә кертергә рөхсәт бирмиләр, хәтта мунчада кундырган өчен дә җәза бирәләр. Комсомоллар һәм дәһриләр (алласызлар) мулла кызларын урам буйлап яланаяк куып йөртәләр, яхшырак киемнәрен салдырып алалар... Бигрәк тә дәһриләр котырына, алар Зәйтуганда хәтта үз хәрәкәтләрен оештырып җибәрделәр, дини бәйрәмнәргә каршы кичәләр уздыра башладылар, халыкны исламга каршы өндәделәр. Мондый алласызлыкны Зәйтуганның әле күргәне юк иде. Дәһриләр бигрәк тә хатын-кызлар өстенә ябырылдылар, аларны дингә, ирләренә, авылдагы тәртипләргә каршы котырта башладылар. Аларны тыярга авылда Асылгәрәй хәзрәт юк иде, икенче мулла Садыйк карт, бу хәлләргә түзә алмыйча, акылга җиңеләеп үлде. Абыстайлар исә кара мунчаларга куып кертелгән иде. Зәйтуган өстенә кара көннәр килде. Авылга тулысынча Шайтан Шакирлар хуҗа булып калды...

Маһинур абыстайга Сабираларда тыныч кына яшәргә ирек бирмәделәр...

Язга чыгу белән, аңа үзенә тиешле җирне эшкәртеп, иген чәчәргә куштылар. Ә абыстайның аты да, сукасы да, орлыгы да юк. Җирне эшкәртмисең икән, димәк, син совет властена каршы... Димәк, сине дә Бөгелмә төрмәсе көтә. Шайтан Шакир бу турыда һәр көн искә төшереп тора.

Һәм Маһинур абыстай, Асылгәрәй хәзрәтнең кадерле хатыны, тугыз баласының анасы, Зәйтуган буйлап өй саен чәчүлек орлык теләнергә чыгып китә. Һәр йорттан бер уч орлык. Көне буе җыя ул аны. Аннан, сукага үзе һәм олы балалары алмаш-тилмәш җигелеп, җирне эшкәртә, үз өлешен чәчә. Шайтан Шакирдан качып кына аларга Сабира белән Гариф та булыша, авыл халкының иманлысы ярдәм итә. Барысы да дөньялар гел болай бармас, бер яхшырыр дип уйлыйлар, Асылгәрәй картның акланып Бөгелмә төрмәсеннән кайтып керүен көтәләр. Аны көткән арада, беркөнне Маһинур абыстайны да алырга киләләр...

Җәйнең иң матур көннәре була бу...

Зәйтуганны әйләндереп алган тау итәкләрендә җир җиләкләре пешкән, әрәмәләрдә карлыган, бөрлегән өлгереп килә. Карчык-коры, бала-чага шунда җыелып ята. Әйтерсең лә Зәйтуганда берни үзгәрмәгән, ярты авылны җәзачылар төркеме кырып салмаган, төрмәләргә илтеп тыкмаган. Әйтерсең лә һаман элеккеге җырлы-моңлы, азанлы-иманлы Зәйтуган. Әмма юк шул, монда инде барысы да үзгәргән, дөньясының асты өскә килгән. Авылдан әдәп, иман качып бара, халык белән ялган һәм янау идарә итә, һәм бу хәл әле бик озак

еллар дәвам итәчәк. Мәскәү, Бөгелмә урыслары куша дип, мулла-абыстайларын таш атып куган татар авылларына бик озак еллар Шайтан Шакирлар хуҗа булыр әле. Мәчетләрне клуб итеп, аракы эчәрләр, мәдрәсәләрне мәктәп итеп, дингә каршы укытырлар. Хәзергә Зәйтуган халкы бу турыда белми әле, ул әле ялган һәм мәкер чорына кереп кенә килә...

Шундый көннәрнең берендә Сабиралар капка төбенә җиккән атлар килеп туктады. Өйлә намазын тәмамлап кына торган Маһинур абыстайның йөрәге дерт итеп куйды, күңеле нидер сизенде, шомланды. Ул арада өйгә Шайтан Шакир һәм таныш булмаган ике урыс кешесе килеп керделәр, аларның кулларында ниндидер кәгазьләр иде.

— Тизрәк җыеныгыз, сезгә моннан китәсе, — диде Шайтан Шакир, керүенә Маһинур абыстайны ашыктыра башлап.

— Кая китим мин җиде бала белән, кая куасың син безне? —дип сорады Маһинур абыстай, тәмам гаҗиз булып.

Ул арада, кайсы тавыш ишетеп, кайсы нидер сизенеп, күрше-күлән, авыл халкы җыела башлады. Асылгәрәй картны кайтаралар дип торганда, Маһинур абыстайны алырга килүләре барысын да шашындырды, куркытты. Хатын-кызлар елаша башлады, ирләр үз алларына сукранды, ризасызлык белдерде. Әмма Шайтан Шакирның кулына килеп ябышырга, бу эшеннән туктатырга курыктылар, чөнки аның янында тагы мылтыклы ике урыс бар иде.

— Сезне Бөгелмәгә озатырга куштылар, аннан нишләргә кирәген үзләре әйтерләр, — диде Шайтан Шакир, бик белдекле кыяфәттә. — Бүген үк илтеп җиткерергә, диделәр, тизрәк мыштырдагыз...

Моны ишетеп, балаларның кайсы елый башлады, кайсы авыл халкы белән саубуллашты, бәхилләште... Әллә кайдан гына тагы авыл активистлары атылып килеп җитте, алар Маһинур абыстай кулыннан мендәр-ястыкларын, табак-савытларын тартып алдылар, үзе белән берни алырга ирек бирмәделәр. Сабира алай да, алар күрмәгәндә, төенчеккә әле бөтен ипиен, әле юлга кирәк-ярагын тутырырга тырышты. Маһинур абыстай исә тиз генә бер кечкенә мендәр эченә Коръән китабын тыгып куйды...

Бер бөтен ипи һәм Коръән белән алар юлга кузгалдылар...

Зәйтуганнан бөтенләйгә чыгып китүләрен алар әле белми иде...

Атка утырыр алдыннан Рәйсәне Зәй суыннан чыгара алмыйча интектеләр. Көн бик эссе иде, ә аяк очыннан гына елга агып ята, бала-чага шунда кайнаша. Ун яшьлек Рәйсә дә күлмәге-ние белән шунда чыпырдый, килеп-килеп чакыргач та, чыкмыйча теңкәгә тиде. Бала күңеле әллә сизенә, һаман: «Бармыйм мин анда, бармыйм», — дип елый. «Анда су

юк», — ди. Әйтерсең лә ул үзенең юлда ук бер тамчы суга тилмереп үләсен белә иде...

Рәйсәне чакка-көчкә арбага менгереп утырткач, Солтанхәкимнең юклыгы беленде. Ул әле иртә белән үк Акман кичүе урманына җиләккә киткән иде, һаман күренми. Инде Шайтан Шакир: «Әйдәгез, кузгалыгыз!» — дип җикеренә үк башлады, ә унбер яшьлек Солтанхәким юк та юк. Маһинур абыстай инде кече улының биредә калуы белән күңеленнән килешкән дә иде... Чөнки аларның кая барасылары, нәрсә күрәселәре билгесез, ә монда әле Сабира апасы бар, ашарга ризыгы, йокларга урыны булачак. Шул чакта югары очтан Солтанхәкимнең йөгереп килгәнлеге күренде, аның кулында кура җиләге белән тулы каен тырысы иде... Ул йөгереп килгән уңайга арбага сикереп менеп утырды, бу ат кая барса, Солтанхәким дә шунда барачак иде. Ни күрсә дә, туганнары белән бергә күрәчәк...

Менә алар, Асылгәрәй хәзрәтнең җиде баласы, ике ат йөгенә төялеп, Зәйтуганнан чыгып китеп баралар. Кая барганнарын алар әле үзләре дә белми. Авыл активистлары аларның яхшырак киемнәрен салдырып алганнар, алар яланаяк, иске күлмәк-ыштаннан, кыз балалар — яулыктан, малайлар — түбәтәйдән, Зәйтуганнан китеп баралар. Инде мәңгелеккә бу яклардан аерылалар. Авыл халкының күпчелеге аларны елап озата, карчыклар Маһинур абыстайдан бәхиллек сорый...

Бәхил бул, Зәйтуган...

Бәхил бул, Зәйтуганга иман нуры китергән Морза Мирзаян нәселе...

Бәхил булыгыз, Зәйтуган таулары — Алыптау, Беләүлетау, Бөркет тавы, Туктартау, Очлытау...

Бәхил булыгыз, Баязит һәм Якуп тарлаулары, Акман кичүе урманнары, Аит сазлыклары, Күкертле әрәмәсе, Даулы аклан...

Әйтерсең лә алар барысы да Морза Мирзаяннар нәселен елап озаталар...

Әйтерсең лә бар табигать алар өчен дога кыла, мөнәҗәт әйтә.

Мөнәҗәтем сезгә булсын, дусым-ишем дога кылсын,
Догалары кабул булсын, аерылдым туганнардин.

Чыгып карыйм бән айларга тәмам унбише җиткәчтен,
Кавышулар читен икән, ерак илләргә киткәчтен.

Туган якка күзем төшсә, башымдин уйларым китә,
Йөрәк бәгъремне яна башлап, түзәргә дәрманым бетә.

Әй, аккошым, китәр булсаң, минем илгә җитәр булсаң,
Туганнарны күрер булсаң, сәлам әйтче син безләрдин.

* * *

Асылгәрәй хәзрәтне Бөгелмә төрмәсендә биш ай тоттылар...

Башта аңа бик ныклап сәяси гаепләр такмакчы булганнар иде — имеш, ул солтангалиевчеләр рәтендә булган, имеш, әле күптән түгел генә Соловкига сөрелгән Атласи белән элемтәдә торган, имеш, алар бергә Туран дәүләте төземәкче булганнар... Аның чит илләрдә укып йөрүен дә, шушы көнгә хәтле Төркия белән элемтәдә торуын да искә төшерделәр. Әмма Асылгәрәй хәзрәт тә нык торды, Солтангалиевне белмәү генә түгел, кабул да итә алмавын, Һади Атласи белән укымышлы кеше буларак элемтә тотуын аңлатты, Туран дәүләтенең кемдер уйлап чыгарган әкият икәнлеген әйтте. Ә инде Төркия мәсьәләсенә килгәндә, ул матбугатны Истамбулдан гына түгел, Мәскәүдән дә алдырып укып ята һәм мәгърифәтле булуның бер гаебен дә күрми...

Идеологик яктан алдыра алмагач, картны совет хөкүмәтенә каршы террор әзерләүдә гаепләргә тырышып карадылар, имеш, ул Зәйтуганда халыкны хөкүмәт вәкилләренә каршы котырткан, аларга каршы һөҗүм оештырган. Асылгәрәй хәзрәт бу вәкил дигәннәренең исерек талаучылар икәнлеген сорау алучының күзенә карап әйтте, бу хакта Мәскәүгә дә язачагын белдерде. «Колхозга көчләп кертү булырга тиеш түгел, бу хакта Сталинның махсус мәкаләсе бар — ул «Уңышлардан баш әйләнү» дип атала, — диде ул. — Ә Зәйтуганга совет власте исеменнән халыкны таларга килделәр, прокуратурадан рөхсәт булмаган килеш, кешеләрне кулга алдылар, җәзаладылар, шул сәбәпле үлү, акылдан шашу очраклары да булды. Моның колхозга ни катнашы бар? Бүген бу төрмәдә мин түгел, Шайтан Шакирлар, шушы эшләрне оештырган район вәкилләре утырырга тиеш иде...»

Шушы рәвешле карттан үзләре теләгән кәгазьләргә кул куйдыра алмагач, башка төрле алымнар эшкә китте. Әлмәттәге бу хәлләрне ишетеп, Казаннан ОГПУ начальнигы Кандыбин үзе килеп җитте. Әле моннан бер ел элек кенә ул урындагы вәкилләренә махсус белешмә-директива җибәргән иде, анда халыкка карата җәза алымнары барысы да җентекләп тасвирланган... Чекистларның урыннарда куллары чишелгән, алар Кандыбин әйткәнне артыгы белән үтиләр. Кандыбин аларны кулак һәм дин әһелләренә каршы рәхимсез көрәшергә, совет дошманнарын тамырларында юк итәргә чакырган иде. Бу кара исемлеккә шулай ук башка төрле фикер ияләре, кайчандыр башка сәяси партияләрдә торучылар, чит илләрдә укучылар, бигрәк тә зыялы интеллигенция вәкилләре дә кертелгән иде. Аларны кулга алырга һәм юк итәргә рөхсәт бирелгән иде. Кандыбин моның белән генә

чикләнеп калмыйча, әле тормышка ашмаган контрреволюцион күренешләрне дә эзләп табарга, киләчәктә советларга каршы эш йөртердәй кешеләрне кырып-себереп түгәргә әмер биргән иде. Асылгәрәй хәзрәт бөтен яктан да ул эзләгән дошман роленә туры килә иде…

Әмма хәзрәттән чекистлар әзерләгән бер генә кәгазьгә дә кул куйдыра алмадылар. Аны кыйнап та, янап та, куркытып та карадылар, әмма ул бар гаепләүләрдән баш тартты. Бөгелмә төрмәсендә аның кебекләр өчен җәзаның яңадан-яңасын уйлап табып тордылар, явызлыкның иге-чиге юк иде. Күпләр, суд булганны да көтмичә, төрмәдә үк үлеп калдылар. Асылгәрәй картның башына тимер кыршаулар тарттырып, аны чүкечләр белән төйделәр, муенына чәнечкеле боҗра кидереп, шуннан өстерәп йөрттеләр, ярасына утлы күмерләр куеп газапладылар, бозлы су астында тоттылар, әмма ул исән калды, бер гаепне дә үз өстенә алмады. Ул гына да түгел, Бөгелмә төрмәсендәге бу хәлләр турында Казанга һәм Мәскәүгә язып җибәрәсен әйтте. Шуннан соң Казаннан Кандыбинның үзен чакырттылар.

Мәһабәт зур гәүдәле, ап-ак чәчле, кыйналса да, горурлыгын һәм кешелек сыйфатларын югалтмаган бу татар картын күрүгә, Кандыбин аның сыйнфый дошман булуын аңлады. Карт белән сөйләшә башлагач исә аның чи милләтче һәм динче икәнлеген дә күрде. Әмма Зәйтуган хәзрәте гаять акыллы, укымышлы кеше иде, ул Мәскәү-Казандагы бөтен законнарны белеп сөйләшә, Кандыбинның да авызын шуның белән генә яба.

— Сез бит бер язмагызда репрессияләр белән бик сак булырга кушкан идегез, — дип, ул шунда ук Кандыбинга аның республика матбугатында басылып чыккан мәкаләсен исенә төшерде. — Контрреволюцион характерда булган күренешләргә генә бәя бирергә куштыгыз. Ә монда авыл халкын талау бара. Совет власте исеменнән теләсә нинди әтрәкәләм кеше талый. Миндә фактлар җитәрлек. Бу бит Сталин кисәткән «бөгеп сындыруга» керә…

Сталин исемен ишеткәч, Кандыбин шабыр тиргә батты.

Бу карт белән сак эш йөртергә кирәклеген ул инде аңлап алган иде. Иң яхшысы — аны тавыш-тынсыз, судсыз-нисез юк итү. Әмма аны яклап авылдашлары, районнашлары күп йөри, күп яза, аларның хәбәре Мәскәүгә дә барып җитәргә мөмкин. Мондагы хәлләр дөньяга чыкса, беркемнең дә башыннан сыйпамаслар, бу канлы тегермән теләсә кемгә каршы әйләнә башларга мөмкин. Шуңа күрә ул, камчы белән алдыра алмагач, картны прәннек белән алдамакчы, үз якларына аудармакчы булды.

— Әйе, хакимияттә очраклы кешеләр шактый, бигрәк тә

авылларда, элеккеге акгвардиячеләр һәм кулаклар властька килергә омтылалар, — диде ул, карт белән өлешчә килешкән булып. — Ә менә сезнең кебек укымышлы кешеләрдән яңа властька ярдәм юк, колхозга да кермәгәнсез, башкаларны да шуңа өндәгәнсез. Бездә дә фактлар җитәрлек бит.

— Колхозга кермәдем, чөнки аның кирәген һәм киләчәген күрмим, — диде Асылгәрәй карт. — Безнең татарда «Уртак малны эт җыймас» дигән мәкаль бар. Тормыш та, мал да уртак була алмый, уртак булса, ул инде беркемнеке дә булмый... Көчләп кертеп, көчләп тотсалар да, мондый уртак тормышның мәгънәсе булмаячак. Талап җыелган мал бәрәкәт бирмәячәк...

— Әмма авылда бөтен кеше дә сезнең кебек бай яшәми бит, ачлар, фәкыйрьләр өчен колхоз, уртак тормыш бердәнбер котылу, исән калу чарасы, — дип каршы төште Кандыбин.

— Ачны, фәкыйрьне колхоз гына туйдыра алмас, анда да эшләп ашыйсы, — дип ипләп кенә каршы төште Асылгәрәй карт. — Әмма аларның эшләгәннәре шәһәрне ашатырга китеп барачак, менә шуның өчен кирәк ул колхоз, пролетариатны ашатырга. Ә инде минем бай яшәвемә килгәндә, мин бай түгел, урта хәлле кеше.

— Урта хәлле? — дип гаҗәпләнгән булды Кандыбин. — Ике катлы таш йорт, утыз-кырык баш умарта, өч-дүрт ат һәм сыер, егермеләп сарык малы, өй тулы яхшы җиһаз, гектарга якын җимеш бакчасы — бу урта хәллегә керәме, Мирзаянов?

— Әмма мин боларны үзем эшләп булдырдым, — диде Асылгәрәй карт тыныч кына. — Өен дә үз кулларым белән салдым, мал-туарын да хатыным һәм тугыз балам белән үзем карадым, җимеш бакчасын да, бөтен дөньядан орлыгын җыеп, үзем карап үстердем. Бу минем кул көчем, хәләл хезмәтем, кеше талап җыйган малым түгел.

— Ә хезмәтчегезне кая куясыз? — дип, аңа каршы төште Кандыбин. — Шакир Шәрипов гомер буе сезгә бил бөккән, хезмәт иткән, сез бит, белә торып, кеше хезмәтен файдаланып баегансыз.

— Шәрип улы бездә хезмәтче булып тормады, тамак хакына йөрде. Аның атасы авылда бердәнбер эчкече иде, хатынын да кыйнап, тилертеп үтерде... Балалары ачка үлмәсен өчен, Шакирын үз яныбызга чакырдык, ишегалдында бераз ярдәм иткәне өчен, бөтен гаиләләрен ничә еллар ашатып, киендереп тордык. Рәхмәт әйтәсе урында, ул безне талап чыгып китте. Һәм сез безне менә шундый кеше талаучы ачлар белән бер әртилгә керергә кодалыйсыз. Үзен хөрмәт иткән кеше ул исерек бандитлар белән сөйләшеп тә тормый, кая анда уртак эш. Болардан рәт чыкмаячак, бездән талап

алганнарны туздырып бетергәч, колхозлары күтәрәмгә калачак...

Кандыбин күрде: картның дәлилләре саллы һәм көчле иде...

Чыннан да, Шайтан Шакир кебек әтрәк-әләм белән яңа тормыш корып булмаячак, ә менә бу карт кебек акыл ияләре башка идеяләргә хезмәт итә. Менә аларны җигәргә иде бу колхоз эшенә, аларны советларга хезмәт иттерергә иде. Әмма боларны башка якка аудару бик авыр шул, димәк, алар алга таба да үз юлларында, үз фикерләрендә калачаклар. Уртак эшкә аяк чалачаклар, комачау итәчәкләр...

— Менә син дә, Мирзаянов, совет властена түгел, халык өчен агу булган дингә хезмәт итәсең бит, — диде Кандыбин, инде «син»гә күчеп, — шуңа күрә колхоз оештырып йөрү Шайтан Шакирларга кала инде. Әйдә, ташла муллалыгыңны, баш тарт динеңнән, алын колхоз эшенә, булыш яшь совет властена, урының да төрмәдә түгел, түрдә булыр... Ә?

Асылгәрәй карт илдә барган бу мәкерле сәясәтне белә иде.

Совет властеның шушы алдавына ышанып, инде күпме дин әһелләре указларыннан баш тарттылар, муллалыкларын ташладылар, шул хакта газеталарга язып чыктылар. Әмма аларны да, йә кулаклар дип, йә башка сәбәп белән, барыбер җыеп алдылар. Башта үз теләкләре белән диннән язарга мәҗбүр иттеләр, аннан башларына да җиттеләр. Эш хәтта анда да түгел. Эш — инануда. Асылгәрәй картны шушы дингә бирелүе, ышануы гына тотып тора да. Ул дөньяда барган бөтен нәрсәгә дин-ислам күзлегеннән чыгып бәя бирә. Адәм балалары өчен зур сынау чоры башланганын ул инде аңлады. Шушы большевикларны, коммунистларны, Сталин һәм Шайтан Шакирларны сәбәпче итеп, Аллаһы Тәгалә барысын да сыный иде. Кем иманда кала алыр, кем динен, үз-үзен сатар, кем сабыр итәр, кем юкка чыгар. Кешелек өчен зур сынаулар әле башлана гына иде. Һәм бу эшләрдә Аллаһы Тәгаләдән башка ярдәм итүче юк иде...

— Әлмәт төбәгендә бер генә мулла калса да, ул мин булырмын, — диде ул, нык инану белән. — Дин тотучы бер мөселман калса да, мин булырмын, иншаллаһ. Милләткә хезмәт итүче бер укымышлы татар калса да, ул мин һәм минем нәселем булыр, Аллаһы теләсә.

Кандыбин аңлады: бу татар картын бер нәрсә белән дә җиңеп булмый иде. Ул үлемнән дә курыкмый, чөнки язмышка, Аллага ышана, аны власть белән кызыктырып, сатып алып та булмый, ул кайда да барыбер үзенекен уздырачак. Ул акыллы, әмма яңа власть өчен куркыныч кеше. Мондыйларны юк итеп кенә котылып була һәм бөтен нәселләре белән

юк итеп. Әмма үлгәнчегә кадәр алар җәһәннәм газаплары күрергә, хайван дәрәҗәсенә төшеп, диннәреннән чыгарга, иманнарыннан баш тартырга тиешләр. Үз теләкләре белән. Башкаларга да гыйбрәт булырлык кара язмышлары белән алар тарихка кереп калырга тиешләр...

Һәм Кандыбин үзенең әүлия битлеген салып атты...

Ул, наганын Асылгәрәй картның маңгаена терәп, аны мәсхәрәли, җәзалый башлады.

— Совет власте синдәйләр көненә калмаган, — диде ул, хәзрәтне аяклары белән типкәли-типкәли кыйнап. — Бу сораулар сиңа сынау өчен генә бирелде. Син үз йөзеңне үзең ачтың, картлач, син яңа власть өчен куркыныч кеше! Һәм совет власте синең черек нәселеңне домна мичләренә салып кайнатачак, алардан яңа кеше ясаячак! Дингә, милләткә каршы интернациональ тимер кеше ясаячак, менә Кандыбин әйтте диярсең!

— Аллаһы Тәгалә моңа ирек бирмәячәк, — ди Асылгәрәй карт, аягүрә басып калырга тырышып. — Татар да бетмәс, дин дә яңадан кайтыр, иншаллаһ!

Аның бу сүзләре урыс чекистын тагы да котырындырып җибәрде, кулларын йодрыклап, ул тагы татар карты өстенә ташланды.

— Менә сиңа динең өчен!

— Менә сиңа милләтең өчен!

— Менә сиңа Солтангалиевләр, Атласилар өчен!

Урыс чекисты һәр суккан саен, татар мулласы аягүрә басып калырга тырышты.

Аңа бу алласыз кяфер алдында тезләнергә, егылырга ярамый иде.

Кандыбин киткәч тә, аның әмере белән суд булганчыга кадәр Асылгәрәй картны һәр көн кыйнадылар, эшләмәгән гаепләрне үз өстенә алырга куштылар, диненнән баш тартырга өндәделәр.

— Алла юк, дип әйт!

Монысы кыйнаучылар әмере.

— Алла бар... Алла бер... Алла бар...

Монысы Асылгәрәй картның сүзләре.

Кан аралаш ул көне-төне шул сүзләрне кабатлый, бер Аллаган гына ярдәм сорый, котылу өмет итә...

Җәй уртасында аңа хөкем карары чыгарылды...

Асылгәрәй хәзрәт 58 нче статья нигезендә, совет властена каршы эшләүдә гаепләнеп, кулак һәм дин әһеле буларак, бөтен гаиләсе белән мәңгелек сөргенгә хөкем ителгән иде... Сөрген урыны итеп Урал аръягындагы Магнитка төзелеше сайланган. Асылгәрәй картның асыл нәселе сөрген шартларында да совет властен куәтләндерү өчен эшләргә тиеш иде.

Хәер, бу җәһәннәм базына эләккән кешеләрнең гомерләре озын булмавын, адәм баласы түзә алмаслык авыр шартларда яшәп, аларның эшләгән җирдән егылып үләселәрен хөкем итүчеләр яхшы белә иде...

Менә аларны, богаулар белән бер-берләренә бәйләп, көчле сак астында Бөгелмә вокзалына куалар. Бирелән аларның бер төркемен Урал аръягына, Чиләбе далаларындагы Магнитка төзелешенә сөрәчәкләр, бер төркемне Казан һәм Мәскәү аша Архангельск якларына урман кисәргә җибәрәчәкләр... Бу мәхбүсләр арасында Мәккә-Мәдинәләрдә укыган меңәрләгән мулла, Төркия-Мисырларда белем алган татар зыялылары, бай һәм хәлле кешеләр күп, монда — милләтнең каймагы. Вокзалга җитәрәк, аларга сөрелгән гаиләләре дә килеп кушыла, китә елаш, китә аһ-зар. Гаиләләре белән кавыша алганнар шушы богаулы бәхеткә дә куаналар, бергә булуларына сөенәләр. Ялгызакларны исә турыдан-туры төрмә һәм үлем көтә, ә гаиләләрен — башка урынга сөрү...

Маһинур абыстай да җиде баласы белән шушы чуар төркемгә килеп кушылды. Башта аларны ачлы-туклы килеш биш көн Бөгелмә монастырендә бикләп тоттылар, хәзрәткә хөкем карары чыгарылгач, аларны да сак астында вокзалга кудылар. Йа Раббым, кемнәр генә юк алар арасында: укытучы һәм язучылар, абыстай һәм затлы мулла кызлары, яңа туган сабыйлар һәм буй җиткән гүзәлләр. Әмма алар бүгенге көннән сөрелгәннәр өммәтеннән, алар әсир һәм туган илләренә кайтудан мәңге мәхрүм ителгәннәр. Моны әле күпләр аңлап та бетерми, үзләрен алда ни көткәнен дә белмиләр алар, белсәләр, шушы Бөгелмә урамнарында ук егылып үләрләр иде...

Июль ахыры, көннең иң челлә вакыты...

Ашарга-эчәргә юк, кешеләр бер кат кием белән торган өйләреннән, авылларыннан куып чыгарылганнар... Әнә мәхбүсләр төркеме яныннан, аларга нидер бирергә итенеп, туганнары йөгерә, кеше башлары аша төенчек-төргәк аталар. Маһинур абыстайның олы кызы Сабира да инде ничә көн аларны поездга төяүләрен көтеп йөри. Ире авылның бер ярлысы һәм граждannar сугышы батыры булгач, Сабирага тимәделәр, әмма Шайтан Шакир гел янап, кемлеген исенә төшереп тора. Сабира, юлга бераз ипи киптереп, сохари ясап, тагы үзенчә кирәк-яраклар алып, әниләрен озатырга килгән. Ул, төенчеген тотып, әсирләр төркеме яныннан йөгерә, аның бу әйберләрен ата-анасына үз куллары белән тапшырасы килә, туганнарын соңгы тапкыр үз күзләре белән күреп каласы килә...

Вокзалга җитә башлагач, инде китәсе мал вагоннары кү-

ренгәч, картлар тәкбир әйтә башладылар, аларның бәхилләшкән авазлары поезд тавышларын да күмеп китте. Бөгелмә өстендә канлы күз яшьләре, елау һәм хушлашу авазлары, тәкбир тавышы эленеп тора иде. Шул чакта кемдер, әллә кайларга яшергән гармунын тартып чыгарып, үзәкләрне өзеп, авыл көен уйнап җибәрде. Бу аерылу газабын, җан ачысын тагы да көчәйтте, күпләр бары тик шушы мизгелдә генә үзләренең туган якларыннан мәңгегә аерылуларын аңлап алдылар. Гармунчы егет тә моны аңлый иде, гармун урынына үз йөрәген ярсып тарта-тарта, үксеп җырлап та җибәрде:

Безнең авыл телеграм
Баганасын кем куйган?
Китәсем килеп китмимен,
Туган илдән кем туйган?

Аңа җавап итеп ачы тавыш белән паровоз кычкыртып җибәрде, кораллы сакчыларның ярсып сүгенгәннәре, балаларның кычкырып елаганнары, картларның бәхилләшкән авазлары ишетелде. Егеткә җырын дәвам итәргә ирек бирмәделәр, берничә сакчы, берьюлы аңа омтылып, гармунны җиргә бәреп төшерделәр, көмеш телләрен кирза итекләре белән таптарга тотындылар. Һәм халыкны, хайваннар кебек, мал вагоннарына таба куа башладылар...

Шул чакта Асылгәрәй карт белән Маһинур абыстай да очрашты...

Хәзрәт нык ябыккан, кыйналган, ак чәчләренә кара кан ябышып каткан, аяк-куллары шешеп, күгәреп беткән иде. Балалар, әтиләрен күрүгә, елап җибәрделәр, абыстай исә хәзрәтенең исән икәнлегенә куанды. Ул арада, халык төркемен ера-ера, Сабира да йөгереп килеп җитте, әнисенә тизрәк үзе белән алып килгән әйберләрне төртте. Алар хәл белешергә дә өлгермәделәр, исемлек буенча сак астында вагоннарга төйи башладылар. Тәрәзәсез һәм ишексез бу тоташ вагоннар мал йөртү өчен җайланган иде, яңа власть өчен хайван өммәтендә йөргән укымышлы татарларны шул вагоннарга кертеп тутырдылар. Монда кеше өстендә кеше, ашарга юк, эчәргә юк, утырырга-ятарга урын юк, тимер вагоннар, эсседә кызып, янар хәлгә җиткән. Һәм шушы вагоннарда халык Урал тауларының кырык сыртын кичәргә, кешесез ач далаларга килеп, шәһәр һәм тимер комбинаты төзергә тиешләр иде.

Асылгәрәй хәзрәтнең асыл нәселе дә шушы юлга чыкты...

Морза Мирзаян нәселен дә, караеп, Урал тауларындагы кеше үтмәслек кырык сырт көтеп тора иде...

Язмышларындагы кырык сырт...

Татар тарихындагы кырык сырт...

* * *

Ир-атын, хатын-кызын, баласын-картын, татарын-урысын, мулласын-побын — барысын бергә җыеп, уртак вагоннарга кертеп тутырдылар. Монда утырырга да, ятарга да урын юк, идәнгә салам җәелгән, кешеләр төркем-төркем шуның өстендә ауныйлар иде. Ашарына булган кеше бәхетле, әмма күпләрне төрмәдән генә алып килгәнгә, үзләре белән бер нәрсәләре дә юк. Маһинур абыстайларның бәхетенә, кызлары Сабира китәр алдыннан гына сохариен, тегесен-монысын китергән иде, өлешләп бүлеп, шуны тоттылар. Әмма монда иң авыры су мәсьәләсе иде. Суны, көненә бер тапкыр тимер ишекләрне ачып, сакчылар чиләк белән таратып йөриләр, әмма күп кешенең су алып калырга савыты юк. Су чиләкләре исә туалет чиләгенә әйләнгән...

Боларны сизгән кебек, Сабира төенчеккә бер калай чәйнек тә тыккан булып чыкты, шуңа су алып калып, тамчылап тоттылар. Әмма тугыз җанга нәрсә инде ул көне буена бер чәйнек су? Шуңа күрә хәзрәт белән абыстай юл буе ураза тоттылар, суны тамчылап балаларына бүлеп бирделәр. Аларның ишле гаиләсенә вагон почмагыннан бер урын туры килде, булган чүпрәк-чапракны шунда җәеп, үзләренчә тәртип ясап, шунда урнаштылар. Мулла белән абыстай шушы шартларда да, бер-берләрен каплап торып, намазларын укып барырга тырыштылар, олырак балалар да шыпырт кына шушы тәртипне тотты. Үз өйләреннән куып чыгарылганнан соң, мунчаларда, кеше почмакларында, Бөгелмә төрмәләрендә куып йөргән гаилә инде авырлыкларга ияләнеп бара иде, монда да түзәргә кирәклеген белделәр. Бара торган урыннарының Урал арты икәнлеген белсәләр дә, күпме барасыларын белмиләр иде. Бу товар поездлары бик әкрен бара, юлда яртышар көн туктап тора, кешеләрне бер җиргә чыгармыйлар, бер нәрсә күрсәтмиләр, бер нәрсә аңлатмыйлар. Болай урап, болгап барса, юлда атна-ун көн үтәчәк тә үтәчәк иде. Ә монда бер көнне үткәрү дә әҗәлгә әйләнә башлады...

Бигрәк тә татар хатын-кызлары интекте...

Кеше алдында хаҗәтен үтәргә өйрәнмәгән, оялган мескен татар хатын-кызлары соңгы чикләренә җитеп түзделәр, берничәсе исә сидек куыклары шартлап үлде. Аларны вагон ишегеннән урманга атып калдырдылар. Берәр атна чамасы шулай баргач, юл түзә алмас газапка әйләнде, тимер вагоннар шартлап кызды, сулыш алырга һава калмады. Күбесенең ашарга ризыклары бетте, эчәр суга тилмерделәр. Моның өстенә каты авырулар, эч китүләр башланды, кешеләр чебен урынына кырылырга тотындылар. Бигрәк тә яшь балалар, картлар, бу хәлләргә түзә алмыйча, мал вагонында җан бир-

де. Сөрген юлы мәхшәргә әйләнде, кемдер салам өстендә бәби таба, кемдер җан бирә, кемдер үкереп елый, кемдер дога кыла, дөнья белән бәхилләшә. Авылларыннан бер җиргә чыкмаган сиксән-туксан яшьлек татар карчыклары, елап, Аллададан сорый, алар: «Йа Раббым, үзең ярдәм бир, хәерлесен кыл, гөнаһларыбыз күп булгандыр, шуның җәзасын күрәбездер», — дип дога кылалар. Бер почмакта әнә татар хатыннары җыелып мөнәҗәт әйтәләр, шулай итеп булса да авыр юлны кыскартасылары, хәлләрен җиңеләйтәселәре килә, ахры...

Фирак уты, фирак уты, сүнәр микән йөрәкләрдин,
Исән чакта кайту насыйп булыр микән ераклардин?

Саба җиле ни хуш икән, кай яклардин исеп килгән,
Хәбәр китермәгән микән безнең илнең тарафындин?

Әйтим микән, җитәр микән, бу кайгылар китәр микән,
Бәнем бу яшь гомерләрем ят илләрдә үтәр микән?..

Кала, кала...

Урман-таулар артында туган яклар кала, яшел болыннар, саф сулы елгалар кала. Туган авыл, туган нигез, кадерле кешеләр кала. Шул чәчәкле болыннарда колын кебек тәгәрәп уйнаган сабый балалар мал вагонында җан биреп ята. Ни өчен?! Туган нигезләрендә, түр башында утырырга тиешле татар картлары, бер тамчы суга тилмереп, аяк астында үлә. Ни өчен?! Туган туфракта ахирәт көнен көтеп ятарга тиешле изге сөякләр юл буйлап сибелеп кала, аларны күмеп торучы да юк. Ни өчен?! Совет власте, колхозлаштыру, гигант төзелешләр шушы корбаннар хакына уздырылырга тиеш идемени? Бай булган өчен генә, укымышлы, иманлы булган өчен генә адәм баласы шушы хәтле газаплар, мәсхәрәләр күрергә тиеш идеме соң? Һәм кеше каны, кеше күз яшьләре өстендә төзелгән бу илнең яшәргә хакы бар идеме?..

Асылгәрәй картлар барган вагонда татарлар бик күп, тирә-күрше авыллардан танышлар да байтак. Әнә Сөләйдән, Кәшер, Колшәриф, Керкәледән, Әлмәттән, Шөгердән, Тайсуганнан, Нәдердән зур-зур муллалар, имамнар, Коръән хафизлар, шәехләр, хаҗилар. Бөтен тирә-якка дан тоткан татар галимнәре, язучылар, фән кешеләре, укытучылар... Нәселле байлар, морзалар, һөнәр ияләре. Совет аларның барысын да бөтереп мал вагоннарына китереп тыккан, үлем сәфәренә озаткан, акыллы һәм хәлле булганнары өчен генә шушындый түбәнлекләргә төшергән. Әмма шушы хәлләрдә дә кеше булып калырга, түзәргә кирәк, юлның ахырын көтәргә кирәк. Ә юлның ахыры барыбер булачак, бу мәхшәрдән исән калганнар аны барыбер күрәчәк, иншаллаһ...

Күпләр инде үзләренең Урал аръягына баруларын беләләр...

Имеш, анда зур төзелеш башланган икән, тимер чыгарып, чуен коя торган завод ясыйлар, ди. Аның бөтен дөньяда тиңе булмаячак икән. Аларны шунда эшкә алып баралар икән. Күпләр моңа куана, ни дисәң дә, Урал Себер түгел инде, туган якларга да якынрак булыр, Себергә караганда җылырак та булыр дип уйлыйлар. Әмма үзләрен анда нинди җәһәннәм көтеп торганлыгын күпләр күз алдына да китерә алмый әле. Кешеләр барыбер яхшыга өметләнә, моннан да авыр булмас дип уйлый һәм бу газаплы юлның ахырын көтә...

Инде Урал тауларына да керделәр, ахры, төннәрен эсселек бераз сүрелә төшкән кебек булды. Әмма көндезләрен бикле тимер вагоннарда тын алырлык түгел, халык суга тилмерә. Товар поезды билгесез станцияләрдә тәүлекләр буе басып, хәрәкәтсез тора, шундый вакытларда бигрәк тә авыр, кешеләр эсседән, һавасызлыктан нишләргә белмиләр. Ачлыктан һәм пычраклыктан барысын да диярлек бет басты, үлемҗитемнең иге-чиге юк. Аларны, әле үлеп тә җитмәс борын, мылтыклы сакчылар өстерәп алып чыгып китәләр һәм вагон ишегеннән тышка атып калдыралар. Уралтау аралары татар балаларының, карт-карчыкларның мәетләре белән тула. Арада инде җиңеләючеләр, акылдан язучылар да күренә башлады, чөнки кеше акылы бу хәтле хәлләрне күтәрә алмый иде...

Әнә Бөгелмә вокзалында гармунын алдырган татар егете, кеше саен сорашып, шуны эзләп йөри. Һаман: «Минем гармунны күрмәдегезме?» — ди... Аның гармунын төрмә сакчылары Бөгелмәдә үк җиргә салып изделәр бит инде, ә ул һаман шуны эзли. Күзләре алышынган, куллары калтырый... Менә ул каяндыр бер такта кисәге табып алган да шуны гармун итеп уйнап утыра, бармакларын ашыга-ашыга күзгә күренмәгән көмеш телләр буенча йөртә. Һәм, мал вагонын яңгыратып, моңлы тавыш белән җырлап та җибәрә:

Әйдә барыйк сахраларга, сахраларга,
Гөлләр араларына, Асылъяр.
Матур яр, гүзәлем,
Өзелә лә үзәгем.

Егет үзе җырлый, үзенең күзләреннән мөлдерәп яшьләре ага...

Ул, ахры, Зәй буйларында калган сөйгән ярын уйлап исәрләнә, мәңгегә аерылганын белеп өзгәләнә:

Безнең хәзер тиң чагыбыз, тиң чагыбыз
Былбыл балаларына, Асылъяр.
Асылъяр, күгәрчен,
Күрми ничек түзәрмен.

Ул калтыранган бармакларын такта буйлап йөртә, аннан һаман гармун телләрен эзли. Юк, гармун телләрен түгел, сөйгәненең йөз чалымнарын эзли, аның белән күрешә, аның белән бәхилләшә:

Яшьлек безнең багыбыз, багыбыз,
Гөлләр өзгән чагыбыз, Асылъяр.
Матур яр, кошкаем,
Аерылабыз, дускаем.

Ул инде уйный да алмый, җырлый да алмый, тактасына капланган да үксеп елый. Аңа ияреп вагондагы халык елый, картлар-карчыклар елый, балалар елый. Татар баласының бу хәтле моңына, аһ-зарына түзә алмыйча, Урал таулары үкереп елый. Үләләрне һәм тереләрне, тилеләрне һәм милләтнең акыл ияләрен төягән хәсрәт арбасы, җырлый-җырлый, елый-елый, кырык сырт аша чыгып бара.

Асылгәрәй хәзрәт белән Маһинур абыстай, соңгы көчләрен җыеп, балаларын саклыйлар. Алар инде үзләренең нинди мәхшәргә килеп эләгүләрен яхшы аңладылар, халыкны бу юлга үләргә дип чыгарып җибәргәннәр иде. Инде һәр гаиләдән берничә мәет бар, авырып, ыңгырашып ятучыларның иге-чиге юк. Инде Асылгәрәй картларның да юлга алган ризыклары бетте, балаларга калганын валчыклап җыеп бирәләр. Әмма иң тилмерткәне су. Су. Шуны да туйганчы бирмиләр бит кешеләргә, хәзер исә бөтенләй кертми башладылар. Моннан бигрәк тә бала-чага, карт-коры интегә, аларның күбесе инде, тапталган салам өстендә чалып ташланган мал кебек, үлем көтеп ята. Мөгаен, алып баручылар аларның берәм-берәм үлеп бетүләрен көтәләрдер, чөнки алар эшкә ярый торган кешеләр түгел бит, ил өчен артык кашык кына...

Асылгәрәй хәзрәт белән Маһинур абыстай күпме генә тырышсалар да, кечкенә кызлары, игезәк сыңары Рәйсәне саклап кала алмадылар. Бала ут эчендә янып бер көн ятты да суга тилмереп, су сорап үлеп тә китте. Әнисенең күзләреннән тамган яшьләре сабый иренендә соңгы шифалы тамчы булды. Авылдан куылыр алдыннан, аны Зәй суыннан чыгара алмый интеккәннәр иде, бала мескен, сизгән кебек, «бармыйм, анда су юк» дип елаган иде. Күрәчәге шулай елаткан икән. Олыгаеп кына тапкан бу балалары бигрәк тә каderле иде хәзрәт белән абыстайга, алар Рәйсә белән Мәрзияне кулда гына йөрттеләр, наз-мәхәббәт белән үстерделәр. Бу игезәк кызлар бөтен гаиләнең яратканы булды, олы балалар аларны курчак урынына карадылар, гөл-чәчәкләр арасында гына тоттылар. Бәхет өчен туган шушы сабый пычрак мал вагонында, бер тамчы суга тилмереп, җан бирде. Ни-

гә?! Ни өчен?! Илгә, совет властена нигә кирәк иде бу корбан?! Бәлки, бу ил, бу империя татар балаларының үсеп кеше булуларын, милләткә, дингә хезмәт итүләрен теләмәгәндер, шуңа күрә туу белән юк итү юлларын уйлап тапкандыр.

Ата белән ана төпчекләрен югалту кайгысыннан шашып калдылар...

Калган балалар, бигрәк тә игезәк сыңары Мәрзия, әле бу хәлгә ышана алмый иде. Әйтерсең лә Рәйсә хәзер зур күзләрен ачар да елмаеп көлеп җибәрер. Ул бит шундый шаян, иркә бала иде, колын кебек гел уйнап тора иде... Ә хәзер әнә керфекләрен дә тибрәндермичә тынсыз ята, ак йөзе тартылып, җитдиләнеп киткән, әйтерсең лә ул башкалар белмәгәнне белә, инде башкалар күрмәгәнне күрә... Аны салам өстенә, идәнгә куярга кызганалар, ул әнисе кулында поезд барган уңайга чайкалып бара да бара... Әйтерсең лә Зәйтуганда әтисе үз куллары белән үргән тал бишектә тибрәлә...

Ә аның гәүдәсен каядыр куярга кирәк, чөнки бу эсседә тиздән ул бозыла башлаячак. Сакчыларга бирсәң, алар аны ишектән тотып кына атачаклар, бала, күмелмичә, ерткыч җәнлекләргә азык булачак. Кая куярга, нишләтергә бу баланы? Ничек аны кешечә кара җиргә тапшырырга? Ата белән ана хәзер бары тик шул турыда гына уйлый иде...

Башта баланы Мәһинур абыстайның шәльяулыгына яхшылап төрделәр.

Асылгәрәй хәзрәт аның өстендә җеназа укыды. Гаилә дога кылды. Аллаһтан ярдәм сорадылар. Шул вакытта, алар бәхетенә, поезд тагы туктап калды, сакчылар бәдрәф чиләкләрен җыеп йөри башладылар. Мәһинур абыстайның үзе белән көмеш беләзеге бар иде, ата белән ана, шуны тотып, Рәйсәнең мәетен күкрәкләренә кысып, ишек төбенә киттеләр. Асылгәрәй карт сакчыга үзе эшне аңлатып бирде, кызын, урманга алып чыгып, агач төбенә күмүен үтенде. Ул арада сакчының кулына абыстайның көмеш беләзеге дә күчеп өлгерде. Сакчы егет як-ягына каранды, аннан курчак кебек төргән бала мәетен тиз генә эләктереп алды да, көрәк тотып, урманга кереп югалды. Шулай итеп, Асылгәрәй хәзрәт белән Мәһинур абыстайның төпчек балалары, игезәк сыңары Рәйсә Уралтауның билгесез сыртында мәңгелеккә ятып калды. Поезд аннан башка гына китеп барды...

Кем белә, бәлки, бу баланың биредә ятып калуы аның өчен яхшырак та булгандыр, чөнки Урал аръягында аларны моннан да газаплы, моннан да авыр хәлләр көтә тора иде...

Урал аръягында бу затлы татарларны иң түбән, иң хокуксыз коллар тормышы көтә иде...

Аларның сөякләре өстендә дөньяда тиңе булмаган тимер гиганты төзелергә тиеш иде...

* * *

Чал Уралның аръягында, аның көньяк-көнчыгыш өлешендәге кыйбла тарафында, гаять серле һәм тарихи урыннар бар. Җаек елгасы буйларыннан башланып киткән бу далаларда туфаннан соң дөньяның беренче кешеләре яшәгән. Бу хакта борынгы тау куышларындагы табылдыклар, шәһәр урыннары һәм исәпсез-хисапсыз курганнар сөйли. Алар биредә йөзләгән, меңләгән. Җаек суы буйлап, Тургай далаларына хәтле, татар җирләре, бөек татар тарихы җәелеп ята. Моннан утыз-кырык мең еллар элек татарлар биредә хуҗа булып яшәгәннәр, зур дәүләтләр тотканнар, Уралның мәрмәр ташларыннан шәһәрләр төзегәннәр, тимереннән эш һәм сугыш кораллары ясаганнар, алтын-көмеше, зөбәрҗәт-фирүзәләре матурлык өчен булган.

Төрле заманнарда бу татарларны төрле исемнәр белән атап йөрткәннәр, алар тоткан ил-дәүләтләр дә төрле исемдә булган. Туран иле, Татар иле, Скиф җире, сөннәр, һуннар, мишәр-болгарлар, кыпчаклар, нугайлар... Төрки каганатлар, Алтын Урда, Себер һәм Казан ханлыклары, Нугай Урдасы. Бу җирләрдә гомер-гомердән татарлар яшәгән һәм шуңа күрә мондагы барлык җир-су атамалары татар исемен йөртә. Әнә совет иле актарып, миллионлаган тонна тимер аласы Әтәч тавы. Аның итәгендә Магнитка шәһәре салыначак. Әнә янәшәдә генә Айдарлы, Карадар, Куйбас, Үзән таулары, Көтек, Яман, Караганлык түбәләре. Татар далаларына мәңгелек ямь һәм яшәү биреп, Җаек елгасы ага, аңа Кызыл, Янгил, Караган, Җигүле, Таналык, Каран, Гөбенә, Сөендек, Уртазым, Үтәмеш елгалары коя. Бу исемнәрне татар җирләренә соңрак хуҗа булып алган урыслар да, коммунистлар да юкка чыгарып бетерә алмаган. Дөрес, моннан ике гасыр элек Әби патша Җаек елгасының исемен Уралга үзгәрткән, шулай итеп, Пугачев белән бергә күтәрелгән татар явын тарихтан мәңгелеккә сызып ташларга теләгән. Әмма ташлый алмаган, татарлар бу елганы һаман Җаек дип йөртәләр, мең еллар элек исә аны гарәп сәяхәтчеләре Олысу дип атаганнар... Сахрадала өчен сирәк кунак булган күлләр дә биредә һаман татар исемнәрен йөртә. Әнә Озынкүл, Чибәркүл, Яктыкүл, Чабаклы, Богодак, Үчәли, Ургун, Карагайлы күлләре... Аларның үзләрен дә, исемнәрен дә замана җилләре бетерә, киптерә алмаган...

Урыслар бу якларга соңгы татар дәүләтләре булган Себер ханлыгы һәм Нугай Урдасы җимерелгәч, XVIII гасыр урталарында килеп урнашалар. 1743 елда атлы казаклар өчен Магнит крепосте салына, татар җиренә урыс хәрбиләре кереп тула. Шушы чордан әкренләп Магнит тавын актару, ан-

нан тимер рудасы эзләү башлана. Һәм китә табигатьне талау. Һәм китә. Алла биргән бушлай байлыкка ия булырга теләүчеләр күп була, Магнит тавы бер купецтан икенчесенә күчеп йөри. Тирләндә һәм Белорет бистәләрендә тимер кою өчен махсус заводлар төзелә, Әтәч-Магнит тавын ныклап үзләштерү башлана. Урыслар бирегә бары тик талау өчен генә киләләр, шуңа күрә бистәне үстермиләр, халыкның хәлен кайгыртмыйлар...

Әмма Магнит тавын чын мәгънәсендә талау Октябрь инкыйлабыннан соң башлана. Галимнәр биредә дүрт йөз миллион тонна тимер рудасы барлыгын ачыклыйлар, советлар һәм партия исә 1925 елда Магниткада металлургия заводлары төзергә карар чыгара. Ул елына алты йөз илле алты мең тонна металл бирергә тиеш була. Әмма советларның бу карарны тормышка ашырырлык инженерлары да, эшче көчләре дә булмый. Һәм алар үзләре куралмаган капиталистларга мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булалар. Дөньяда тиңе булмаган тимер гигантының проектын Америка инженерлары эшләп бирә, комбинат өчен эш җиһазлары океан артыннан китерелә, төзелештә төп белгечләр дә америкалылар, немецлар, чехлар, болгарлар, итальяннар, финнар, румыннар, төрекләр була. Әмма 1933 елда, комбинат инде эшли башлап, беренче чуенны биргәч, чит ил белгечләре белән тизрәк араны өзәләр һәм аларны инде беркайчан да искә алмыйлар. Илләренә кайтып китәргә өлгермәгәннәрен Себер төрмәләре көтә...

СССР өчен иң катлаулысы Магниткага эшче көчләр туплау була...

Чөнки бирегә кызыл байрак күтәреп, калай әтәчләнеп килгән комсомол-активистлар авыр эштән бик тиз шәлперәеп төшәләр, тизрәк качу ягын карыйлар. Биредәге кеше түзә алмаслык шартларда өч айдан артык беркем чыдамый, килгән кешеләрнең сиксән-туксан проценты гел кача. Ә йөзәрләгән гектарга сузылган тимер гигантын төзергә, алай гына да түгел, төзегәч, анда эшләргә, тимер коярга, шәһәр салырга кеше кирәк! Аларны каян алырга? Советлар һәм Сталин монда да аптырап калмыйлар, колхозлаштыру һәм кулаклар мәсьәләсен уйлап табып, авыл халкын бөек төзелешләргә, шул исәптән Магниткага да сөрә башлыйлар. Бер Урал өлкәсенә генә дә ярты миллион кеше сөрелә. Магниткага һәр көн эшелон-эшелон тоткын китереп ташлыйлар...

Аларның күпчелеге татарлар була...

Аларның күпчелеге шушы төзелешләр вакытында үлеп бетә...

Магнитогорск шәһәре һәм биредәге металлургия комбинаты татарларның сөякләре өстенә төзелә...

Кырым татарларын һәм Кавказ халыкларын 1944 елда

илләреннән сөрсәләр, Идел буе татарлары өчен бу сөрген чоры утызынчы елларда ук башлана.

Халыкның бер өлеше юлда барганда ук үлеп кала, бер өлеше Магнитка төзелешендә корбан була, бер өлеше генә бу тәмуг газапларыннан исән кала.

Әнә ул татарлар, мал вагоннарыннан төшеп, үзләренең киләчәкләренә карап торалар. Атналар буе эсседән, сусызлыктан, ачлыктан һәм авырулардан газапланган, бетеренгән кешеләрне таң алдыннан кипкән далага чыгарып бушаттылар. Ул мескеннәр монда да шат, чөнки алар, юл мәхшәреннән исән калып, каты җиргә аяк баса алдылар. Монда алар туйганчы саф һава сулый алалар, бәлки әле, эчәргә су, ашарга ризык та булыр дип өметләнәләр. Әмма аларны бөтен яктан этле, мылтыклы сакчылар урап алган, бу татарлар читкә бер адым да ясый алмыйлар. Чөнки алар монда ирекле булып түгел, кол сыйфатында китерелгәннәр иде...

Кешеләр, кузгалырга әмер булганны көтеп, күч-күч булып җыелдылар, кем тизрәк җиргә утырырга ашыкты, кем сузылып ук ятты. Август төне шактый салкынча иде, кешеләр бер-берләренә сыенып җылынырга тырыштылар. Әкренләп таң беленә башлады, каршыда томан арасыннан таулар калкып чыкты, тирә-якта тоташ дала иде. Җирдә ник бер үлән заты булсын, аяк астындагы кызыл туфрак кыштырдап тора, тирә-якка көйгән ис таралган. Ерак түгел, атлас тасмадай елкылдап, зур су җәелеп ага, Җаек дигәннәре шулдыр, мөгаен.

Иртәнге якта бераз салкынча кебек тоелса да, көндез тагы кыздыра башлады, зәһәр дала кояшыннан беркая качар урын юк. Иң авыры — халык һаман бер тамчы суга тилмерә, эчәсе килүдән газаплана. Тирә-якта тездән кайнар ком, актарылып ташланган кызыл балчык, көйгән дала җәйрәп ята иде. Биредә җәй буе яңгыр яумаган булып чыкты, ә җил исә кайнар ком гына китерә. Ул аны учлап битләргә бәрә, теш араларына тутыра, күзләрне каплый. Ямь-яшел болыннардан, шаулап утырган урманнар иленнән килгән татарларга бу җир башта ук котсыз һәм ямьсез булып тоелды. Әмма, ни генә булса да, бу аларның торыр җирләре иде. Мәңгелеккә сөрелгән илләре иде. Аларның берсендә-бер документ та юк, паспорт та юк, алар хәтта хат язарга һәм алырга да хокукы булмаган әсирләр иде. Һәм аларга шушы хәлләренә, шушы кырыс һәм коры табигатькә ияләнергә кирәк иде...

Мылтыклы һәм кинжаллы сакчылар чолганышында, чатнап торган дала кояшы астында аларны торыр җирләренә алып киттеләр. Озак, бик озак барды алар кипкән, актарылып ташланган үле җир буйлап. Хәле бетеп егылганнар өстенә эт өере ташланды, үлгәннәрне бер читкә ата бардылар,

бу хәлләрдән шашынган халыкны мылтык белән алга кудылар. Кешеләр, егылмас өчен, бер-берләренә ябыштылар, тизрәк бу юлның азагын көттеләр. Балаларга хәтле тынып калды, карт-карчыклар туктаусыз дога кылды, барысының да күңелләренә шом керде…

Менә аларны тау битендәге коры җиргә китереп ташладылар…

Кешеләр, гаҗәпләнеп, як-якларына карадылар — монда яшәү өчен бернинди бина-мазар күренми, йорт-җирнең эзе дә юк иде. Газаплы юлдан, ачлыктан, сусызлыктан тәмам хәлсезләнгән халык гөрселдәп җиргә ауды, күпләргә инде кайда егылып үлсәләр дә барыбер иде, тик бу газапларның гына ахыры булсын. Әмма алар өчен бу газаплар башлана гына иде әле, алар шуны белмәүләре белән бәхетле иделәр. Аларны һаман да шул мылтыклы сакчылар чорнап алган, ашарга эзләп тә, су эзләп тә беркая бара торган түгел, барысын да хисапка алып бетермичә, читкә аяк атларга да ярамый иде. Алар килеп төшкән как җир чәнечкеле тимерчыбыклар белән уратып алынган, аларның һәрберсенә номер беркетелгән, сакчы куелган. Илдән сөрелгән татарлар өчен төрмә тормышы башланган иде. Концлагерьларны, әле Гитлерга кадәр үк, совет режимы һәм Сталин төзетте, һәм анда, беренче тоткыннар булып, татарлар ябылган иде…

Ә аста…

Ә аста, киң үзәндә, бөҗәкләр кебек кешеләр кайнаша.

Аларның исәбе-хисабы да, саннары да юк, әллә ничә дистә мең булыр. Һәрберсе каядыр ашыга, кайсы тачка тотып йөгерә, кайсы, аркасына әрҗә куеп, кирпеч ташый, кайсылары котсыз тирән базда кайнаша, боҗра-боҗра итеп шуны казып төшә. Иртәгә үк бу яңа килгән татар тоткыннары да шулар арасына кереп батар, кайсы кирпеч ташыр, кайсы җир казыр, кайсы бетон болгатыр. Кайсы шунда тәгәрәп үлеп калыр. Бу татарларны һәр көн мылтык астында эшкә алып барырлар, мылтык астында алып кайтырлар. Мондагы төзелешнең иге-чиге күренми, китереп ташлаган тимер-томырның, актарып ташланган җирнең исәбе юк. Ара-тирә йөк машиналары, трактор кебек техника да күренә, әмма алар бик аз, шуңа күрә бөтен нәрсә кул көче белән башкарыла. Һәм шушы тәртипсез рәвештә тузгып яткан тау-таш өеменнән завод һәм шәһәр үсеп чыгарга тиеш иде.

Тоташ завод торбаларыннан торган ул шәһәр Магнитогорск дип аталачак.

Чабаталы татарлар төзегән металлургия комбинаты дөньяда иң куәтлеләрдән булачак.

Ул инде өлешчә бар да, тик агач бараклардан, палаткалардан һәм җир куышларыннан тора. Җаек елгасына кар-

шы йөзләгән, юк, меңләгән казарма-бараклар, брезент палаткалар тезелеп киткән. Америка белгечләреннән һәм урыс җитәкчеләреннән кала, бөтен эшче халык шуларда яши. Кибет, клуб, ашханә, почта, медпункт кебек тораклар да баракларга урнашкан. Сөрелгәннәр биредә, зур-зур бистәләргә бүленеп, аерым яшиләр, әмма алар шулхәтле күп, торырга урын өлгертә алмыйлар. Менә бүген дә шундый бер төркемне коры җиргә китереп ташладылар, алар өчен яшәргә урын әзер түгел иде...

Асылгәрәй хәзрәтнең ишле гаиләсе бер тирәгә укмашты...

Чәйнек төбендә бераз җылы су калган икән, шуны кечерәк балаларына бүлеп бирделәр, соңгы сохари валчыкларын җыеп ашаттылар. Ата-ана менә ничә көн инде үзләре ачлар. Хәер, аларга ризык бармас та иде, чөнки күз алларында һаман төпчекләре Рәйсә, аның тилмереп үлүе тора. Игезәк сыңары Мәрзиягә караган саен, аның янында Рәйсәне дә күргән кебек булалар, чөнки алар гел бергә иделәр. Инде җиде баланың берсе юк, әҗәл юлы аны гаиләдән суырып алды. Хәзрәт белән абыстайның калган балаларына, үзләренә дә шушы ук хәл яный иде. Инде әнә, монда хәтле килеп җиткәч тә, берничә кеше егылып үлде, аларга хәтта игътибар итүче дә юк. Асылгәрәй карт менә хәзер генә НКВД начальнигы Кандыбинның ни өчен үзен Бөгелмәдә үк атып үтермәвен аңлады. Ул Асылгәрәй карт һәм аның балаларының менә шушы утлы җәһәннәм аша үтеп, янып үлүләрен теләгән... Хайванга әйләнүләрен теләгән. Әмма Аллаһы Тәгалә бар әле, инде ни булса да, бары тик аннан гына ярдәм көтәргә кала иде...

Илләреннән сөрелгән татарлар буш далада, инде суынып өлгергән ком өстенә ятып, беренче төннәрен чыктылар. Еракта ач дала бүреләренең шомлы тавыш белән улаганнары ишетелә. Түбәндә, завод төзеләсе урында, һаман нидер шартлаталар, җимерәләр, актаралар, әллә җир, әллә хәлдән тайган кешеләр ухылдый — аңларлык түгел. Монда көн-төн дигән нәрсә юк икән, борып җибәргән сәгать кебек, бөтенесе хәрәкәттә, бөтенесе эштә. Монда җирнең генә түгел, дөньяның асты өскә килә, кешеләрнең тәннәре һәм җаннары актарыла. Монда адәм баласын социализм казанына салып кайнаталар һәм аннан яңа кеше ясыйлар. Исән кала алса, әлбәттә...

Асылгәрәй хәзрәтнең ишле гаиләсе Магниткада беренче төнен куна...

Әнә ата белән ана, җан җылыларын биреп, балаларын туңдырмаска тырышалар, дала кошлары кебек, аларның йокыларын саклыйлар. Буй җиткән кыз Гайшәбикә, үсмер егет Гыйлемгәрәй, Сәгыйть белән Саҗидә, Солтанхәким белән Мәрзия. Гөлләр арасында Коръән ятлап, намаз укып үскән

иманлы, тырыш авыл балалары. Төшләрендә, мөгаен, Зәйтуганның җиләкле әрәмәләрен, саф сулы чишмәләрен күрәләрдер, чәчәкле болыннарында йөгереп йөриләрдер. Хәзер, бер телем ипигә, бер тамчы суга тилмереп, ач далада ауныйлар. Ни өчен? Гыйлемле, иманлы татар булганнары өченме? Нәрсә көтә аларны алда бу тимер казанда? Ил алардан да тимер кешеләр ясап чыгарырга әзерләнәме? Иманнарын, телләрен, диннәрен тартып алырга җыенамы? Әллә гомерләренә үк кизәнәме? Шушы кадерсезлекләргә төшереп, алардан хайван ясарга телиме? Мөгаен, шулайдыр, чөнки монда адәм баласы хайваннан да түбән дәрәҗәгә куелган, хайванны да җылы абзарга ябалар, алдына ризык һәм су куялар. Ә монда үлгән кешеләрне дә җыеп алучы күренми, алар башкалар белән бер җирдә ауный бирәләр...

Икенче көнне мылтыклы сакчылар алар яткан урынга озын брезент палаткалар өстерәп китереп ташладылар... Татар тоткыннары хәзер шунда яшәргә тиешләр иде. Моны белеп, халыкның коты чыкты. «Бу чүпрәк шалашларда ничек итеп кыш чыгарбыз икән?» — дип ут йотты алар. Бу тоташ чатырларга татарлар бергәрәк керергә тырыштылар, Асылгәрәй карт гаиләсе дә Әлмәт-Шөгер тирәләре белән урнашты. Хәзер алар барысы бергә: ире-хатыны, яше-карты, бала-чагасы бер түбә астында яшәргә тиешләр иде. Ике-өч гаиләгә бер кечерәк палатка туры килгән очраклар да булды, әмма монда да кеше өстендә кеше иде. Әмма, ни әйтсәң дә, эссе кояш астында җирдә яту түгел, үз почмагың, түбәң бар. Әле гомергә монда калдырмаслар, әнә теге үзәнлектәге агач баракларга да күчерерләр дип өметләнделәр... Кешеләр, әнә шулай уйлап булса да, үз-үзләрен юатырга тырыштылар, хәлләренең бер яхшыруына өметләрен өзмәделәр...

Ике атнага якын юлда мал вагоннарында аунаган халык бик керләнгән, бетләп беткән иде, ә мунча юк. Кая анда мунча, һаман ашарга ризык, эчәргә су бирмиләр, ә эшкә куалар. Икенче көнне үк ир-атларны баз-котлован казырга, хатын-кызларны кирпеч ташырга алып киттеләр, йөри алмаслык карт-карчыклар һәм бала-чага гына палаткаларда калды. Асылгәрәй карт гаиләсе дә бер көн эчендә эшче колга әйләнде — хәзрәт белән олы улларын котлован казырга куйдылар, абыстай белән зур кызлары аркаларына кирпеч әрҗәсе астылар. Һәр көнне иртәнге караңгыдан рәткә тезелеп эшкә чыгып китәләр, кичке караңгыда гына кайтып авалар. Аларны алдан-арттан, ян-яннан этле сакчылар озатып йөри, читкә чыксаң да, артка калсаң да — бер көнлек төрмә. Эшкә чыкмасаң, өлеш ипиеңне бирмиләр, бу исә ачка үлү дигән сүз...

Бәхеткә, Солтанхәким белән Мәрзия хәзергә палаткада

калды. Ул балалар, гаилә эштән кайтып егылуга, Урал елгасыннан су ташып куялар иде. Суга хәтта балаларны да сак астында алып баралар икән. Әмма нигәдер Урал суы кыпкызыл булып чыкты, кешеләр моны күреп куркышсалар да, чыдый алмагач, эчтеләр һәм тагы чирли, кырыла башладылар. Асылгәрәй хәзрәт башта ук кайнамаган су эчүне катгый рәвештә тыйды, моны тыңлаган кешеләр исән калды, тыңламаганнары эч китүдән бетте. Маһинур абыстай, һәр төнне кырда учак ягып, су кайнатты, аннан-моннан ризык юнәтеп, ашарга әтмәлләде. Солтанхәким белән Мәрзия һәр көн Урал суы буеннан үлән җыеп кайталар иде, алар да пешереп ашарга ярап торды.

Балаларның бик йөдәгәннәрен күргәч, хәзрәт белән киңәшләшеп, Маһинур абыстай соңгы көмеш беләзеген ризыкка алыштырды, бераз ипи, сөт-май, йомырка юнәтте. Биредән ерак түгел казах авыллары бар икән, алар шулай бистәгә килеп, сату-алу итеп йөриләр. Маһинур абыстай ризыкны тигезләп күп өлешләргә бүлде, алдагы көннәргә дә ашарга калдырды. Башта балалар ул ризыкларга кагылырга да куркып тордылар, бу хәтле нигъмәткә могҗизага караган кебек карадылар. Аларның, Зәйтуганнан сөрелгәннән бирле, авызларына юньле ризык капканнары юк иде инде. Маһинур абыстай бигрәк тә хәзрәте өчен борчылды, Бөгелмә төрмәсендә кыйналганнан соң, аның әле һаман рәтләп тернәкләнеп китә алганы юк иде, җитмәсә, килү белән авыр эшкә куйдылар. Шуңа күрә ул, үз авызыннан өзеп булса да, ирен ашатырга, аны аякка бастырырга тырышты. Балалар исә кыенсынып кына ризыкка үрелделәр, һәр валчыкны, һәр бөртекне озаклап авызларында тотып, тәменнән исәрләнгәндәй утырдылар. Моны күреп, Маһинур абыстайның күзләренә яшь килде, ул, балаларын ач тотмас өчен, җир асларына төшәргә дә риза иде...

Өзелергә торганда шушы рәвешле ялгап җибәрү аларны ач үлемнән саклап калды. Ә күпләр бетте, бигрәк тә Уралның пычрак суын эчеп кырылучылар күп булды. Моны күреп, сакчылар биш чакрым ераклыкта булган Әтәч тавына суга барырга рөхсәт иттеләр, чөнки аларга көн дә эшкә чыгарга исән кешеләр кирәк иде. Август ае булса да, көннең кызуы сүрелми, аяк астында кызыл ком очып тора. Мондый вакытта сусыз бернишләп тә булмый, халык кая рөхсәт итсәләр, шунда бара. Әтәч тавындагы су шактый чиста, эчәргә яраклы булып чыкты, әмма ул да ябык зона эчендә, тимерчыбыклар белән чорнап алынган иде. Биредә кешеләр генә түгел, чишмәләр дә тоткын хәлендә иде...

Ул арада Татарстаннан тагы эшелон-эшелон тоткын килеп төште...

Кемнәр генә юк иде алар арасында! Иң зур муллалар, шәехләр, хаҗилар... Иң зур галимнәр, зыялылар, мәгърифәтчеләр. Әйтерсең лә кемдер татарны тамырыннан юк итәргә алынган...

Әлмәт, Балтач, Саба яклары халкы, Болгар, Апас, Кайбыч татарлары... Кайсы кулак буларак бу кара исемлеккә эләккән, кайсылары мулла-ишан буларак гаиләләре белән туган җирләреннән сөрелгән. Күбесендә инде гаилә башлыклары юк, аларны атканнар, ә балаларын бирегә сөргәннәр... Туксанга җиткән ак сакаллы татар картларына, ак яулыклы татар карчыкларына карап, йөрәк шартлап ярылыр хәлгә җитә. Аларның күбесе кайда, ни өчен сөрелгәнен әле һаман аңламый, әмма бирегә үләр өчен китерелгәннәрен сизенәләр... Сизенәләр...

Шуңа күрә алдан килгәннәр аларга кулларыннан килгәнчә ярдәм итәргә тырышалар. Кем үз тирәсенә палаткага сыендыра, кем юлда бетләп беткән мескен халыкка су юлын күрсәтә, кем соңгы кисәк ризыгы белән бүлешә. Үлгәннәрне кешечә күмәргә, исәннәрне кеше хәлендә саклап калырга тырышалар. Үзе дә сизмәстән Асылгәрәй карт бу эшләрне башлап, оештырып йөрүчегә әйләнеп китте. Нинди хәлдә дә кеше булып калырга кирәк иде. Кеше үлсә, аны кешечә күмәргә кирәк, һәм картлар яшереп кенә җеназа укыйлар иде. Бала туса, яшереп кенә аңа ислам тәртибе белән азан әйтеп, исем кушалар, яшьләр өйләнешсә, качып кына никах укыйлар. Шушы брезент палаткаларда да олы як яшереп намаз укый, ураза тота, дин-ислам чикләреннән чыкмаска тырыша. Кеше түзә алмаслык шартларга килеп эләккән татар яшьләрен дә канга сеңгән әдәп-әхлак тота, кешелек чикләреннән чыгармый. Татарлар, бергә укмашып, исән калырга тырышалар. Ә бит биредә аларны җансыз тимер кешегә яки акылсыз хайванга әйләндерү максаты куелган. Алар шуның өчен бирегә китерелгән, әмма татарлар бу хакта хәзергә үзләре белмиләр иде...

* * *

Уралда кыш иртә килә икән.

Әле генә чатнама эссе иде, аяк астыннан кайнар ком очып торды, ә хәзер әнә кара давыл котыра. Җәй буе яумаган яңгыр үзенекен куып җитәргә уйлый, ахры, бөтен яктан да китереп бәрә. Дала буйлап чүп-чар оча, төзелештә нәрсәләрдер дөбердәп җимерелеп төшә, брезент палаткалар җир белән тигезләнә. Кешеләр урын-җирләрен, соңгы өс-башларын, ризыкларын коткарырга теләп, җиргә капланып яталар, котырган давыл аларның үзләрен дә дала буйлап тәгәрәтеп алып китә.

Шулай бер яңгыр, бер кар явып торды да, кинәт кенә туңдырып җибәрде. Октябрь урталарында инде чүпрәк палаткалар ап-ак кар эчендә утыра иде. Котып ягыннан үзәкләргә үтәрдәй салкын җил исә, ул арык тәннәрдәге соңгы җылыны да суырып ала. Айга бер тапкыр бирелә торган чабаталар инде өзелеп, тетелеп чыкты, кешеләр аларны эшкә күтәрмә тагып кия башладылар. Ә эшкә чыкмыйча ярамый, ашарга эшләгән кешеләргә генә бирәләр иде. Сәбәпсез эшкә чыкмавыңны белсәләр, төрмәгә үк утыртып куялар.

Салкыннан кая барырга белмәгән кешеләр җир куышлары казып керә башладылар. Әмма аңа да рөхсәт кирәк иде, ә рөхсәт бер гаилә өчен генә бирелми, салкын җир куышларына да әртил белән куып кертәләр. Ягарга да күмерне үзеңә табасы. Инде кара җир өстендә катып үлгәнче, җир астына керергә торганда, Асылгәрәй картларның гаиләсен, бөтен палаткалары белән бергә, тоткыннар бистәсендәге баракларга күчерә башладылар. Халык башта моңа сөенсә дә, бу буш тартмаларны күреп, котлары чыкты. Аларның ни түбәсе, ни тәрәзәсе, ни ишекләре юк иде. Урам ягыннан әле кар, әле боз бәреп керә, казах далаларыннан ачы салкын җил исеп, үзәкләрне өзә. Шушында кыш чыгасыларын уйлап, кешеләр кара кайгыга төштеләр, әмма аларның башкага хокуклары юк иде. Һәм мир белән җыелышып, кем нәрсә эшли ала, шуны булдырып, баракларны рәткә китерергә тотындылар.

Кеше башына ярты адымнан исәпләп, Асылгәрәй картның ишле гаиләсенә баракта дүрт метр урын туры килде. Ашау да шунда, яшәү дә, сигез җан шунда сыярга тиеш. Ике йөз илле кешегә исәпләнгән баракка дүрт йөз кеше шыплап тутырылган бу озын казарма куркыныч төрмәне хәтерләтә иде. Төрмәдәге кебек монда да дүртәр рәтле нар-сәкеләр, кеше өстендә кеше, чаршау-фәлән корырга ярамый, бөтенесе дә сакчыларның күз алдында булырга тиеш. Шушында ук бәби табалар, шушында ук егылып үләләр, шушында ук урысы, татары, чувашы. Бандиты, мулласы, карагы. Көнгә бер тапкыр шәһәр ягыннан ипи китерәләр, аны, тактага салып кисеп, телемләп тараталар. Ул ипи чи була, балчык кебек лычкылдап тора, аның бернинди тәме юк. Әмма ул да эшкә чыккан кешеләр өчен генә бирелә, авырып калсаң, ул ипи дә юк, һәм кешене ач үлем көтә. Суны исә чиләкләп тагы Урал елгасыннан ташый башладылар, чөнки кышкы якта кар арасыннан ачлы-туклы килеш Әтәч тавына барып җитәрлек түгел. Озын казарма-баракта ике тимер мич тора, утыны булган кеше, зур чират торып, анда чәй кайната ала. Бу да кешеләр өчен зур бәхеткә санала.

Әмма иң авыры һаман шул ипи мәсьәләсе, чөнки халыкның бөтен карап торган азыгы шул. Хәзер аны кулга тот-

тырмыйлар, карточкага гына бирә башладылар. Кулда кәгазе булса да, ипие ике-өч көн буе булмый, булса да, аны тоткыннар бистәсенең читенә барып, төннәр буе чират торып алырга кирәк. Ул чиратта исә талаш, янау, урлашу, үлем. Әле ул өлеш ипиеңне алгач, баракка хәтле саклап алып кайтырга кирәк, чөнки караклар монда да җитәрлек, карт-корыны, бала-чаганы кычкыртып талыйлар, беркем ярдәмгә килми. Алып кайтып, барак сәкесендә калдырсаң да, ипиең юкка чыгарга мөмкин, чөнки бирекдә барысы да ач, бигрәк тә балачага. Шуңа күрә, урамга бәдрәфкә чыкканда да, кешеләр янчык белән ипиләрен тотып чыгарга мәҗбүрләр. Әмма аларны еш кына аннан да талап кертәләр. Кешеләр монда хайван хәленә куелган, һәм инде күпләр хайванга әйләнеп баралар иде.

Алар барагыннан Мәрьям исемле Теләче ягы хатынын шул ипи чиратында кысып үтерделәр. Маһинур абыстай үзе дә анда иде, ул олы улы Гыйлемгәрәй белән төннән торып чиратка баскан иде. Ничә көннәр буе ипи чырае күрмәгән ач халык, аның бөтен кешегә дә җитмәслеген белгәч, котырып алга ташланды. Китте бер-берләрен таптау, изү, кычкырыш, елаш. Маһинур абыстай, улын алып, тизрәк читкә чыкты, чөнки мондый вакытта шашкан халык таптап үтерергә дә мөмкин иде. Мәрьям, мескен, чыгып өлгерә алмаган, ул авырлы иде, инде бала табар вакыты җитеп килә иде. Аның ире юлда ук үлеп калды, балалары исә берсеннән-берсе кечкенә, берсе дә эшләп ашарлык түгел. Аларны ачка үтермәс өчен, борынга җиткән корсагы белән Мәрьям үзе эшләп йөри, төннәр буе ипи чиратында да үзе басып тора. Һәм салкын декабрь төнендә аны корсагындагы баласы белән бергә кысып үтерделәр. Мескен Мәрьям, татарча ачыргаланып кычкырып, «Балам, балам!» дип үлде. Соңыннан Асылгәрәй хәзрәтләр аны, чанага салып, тумаган баласы белән бергә, далага алып чыгып күмделәр. Балаларыннан бер Сафия исемле кызлары гына исән калды.

1931 елның декабре гаять салкын һәм иртә килде...

Кешеләр баракларга күчеп, тишек-тошыкларын ямап өлгермәделәр, коры салкыннар китереп бәрде. Бу әллә нинди шыксыз, карсыз, ачы җилле кыш иде. Кар урынына биткә салкын ком бәрә, баракның һәр тишегеннән эчкә бозлы ком тула. Сөргенгә сөрелгән татарлар өчен бу чын мәгънәсендә үлем кышы булды, һәр гаиләдән өчәр, хәтта дүртәр бала бу кышта үлеп калды. Салкыннан, ачлыктан, тифтан кырылды ул сабыйлар. Баракларда, чын мәгънәсендә, тиф котыра башлады, моннан исән калу мөмкин түгел иде, чөнки ач бетләр бу зәхмәтне кешедән кешегә таратып йөрделәр. Асылгәрәй хәзрәт белән Маһинур абыстай үзләре белгән бөтен чаралар

белән балаларын тифтан сакларга тырыштылар, әмма әҗәл баракка кереп урнашкан иде инде. Иртәнге сәгать алтыда, әле кап-караңгыда, бригадирлар баракка кешене эшкә куарга керәләр, кемдер тормаса, аны аягыннан өстерәп төшерәләр. Ул кеше инде йә үлгән була, йә, хәлсезләнеп, үлем көтеп ята. Кышкы урамнар, барак тирәләре күмелмәгән мәетләр белән тулды, больницалардан исә үлгәннәрне туп-туры уртак чокырларга илтеп ташлыйлар иде...

Магнитка төзелеше менә шулай башланды, шәһәр һәм металлургия комбинаты нигезенә менә шулай меңләгән мәетләр, корбаннар салып калдырылды.

Аларның күпчелеге татарлар иде.

Маһинур абыстай балаларын никадәр чисталыкта, тәртиптә тотарга тырышса да, мондый шартларда ул мөмкин хәл түгел иде. Алай да алар бу кышта үзләрен дә, балаларын да ачлыктан һәм тифтан саклап кала алдылар, ә менә бәхетсезлектән саклап кала алмадылар. Бәхетсезлек алар гаиләсенә иң нечкә җирдән — балалар аша һөҗүм итте. Маһинур абыстайны иң борчыганы ачлык та түгел, ялангачлык иде. Балаларның эшкә кияргә җылы киемнәре юк, алар тишек чабатадан, чүпрәк-чапракка уранып, һәр көн таң белән эшкә чыгып китәләр. Баракта Солтанхәким белән Мәрзия генә утырып кала, аларга гаилә почмагын тәртиптә тотарга кушылган. Калганнар кара төнгә хәтле эштә. Аларның барысын да, ач килеш, мылтыклы сак астында, һәр көн унике чакрым кырга эшкә куалар. Асылгәрәй карт, олы уллары Гыйлемгәрәй һәм Сәгыйть белән бергә, ирләр төркемендә җир казырга бара, алар көрәк һәм кәйлә белән уникешәр сәгать котлован казыйлар. Үлгән кеше шунда шыкыраеп катып кала, кайвакытта аларны актарып алучы да булмый. Хатын-кызлар исә домна мичләрен төзергә җилкә белән кирпеч ташый. Җилкәдә — «кәҗә» дип йөртелгән беркетелгән әрҗә, әрҗәдә унар кирпеч, шуны йөз баскыч югарыга менгерергә кирәк. Бер караңгыдан икенчесенә хәтле ул баскычлардан меңәр тапкыр күтәрелергә туры киләдер. Маһинур абыстай олы кызлары Гайшәбикә һәм уртанчы кызы Сажидә белән шул кирпеч эшендә. Сажидәгә бигрәк тә авыр, чөнки әле аңа унөч яшь тә юк, буыннары ныгымаган, өс-башы юка, ашау такы-токы. Ә эшкә чыгу — мәҗбүри, төзелеш җитәкчеләре өчен ул бала түгел, тоткын, кол.

Менә бүген дә аларны таң белән кырга кудылар, ир-атларны — чокыр казырга, хатын-кызларны — кирпеч салырга. Шушы көннәрдә беренче домна миче сафка басарга тиеш иде, шуңа күрә халыкны кырык градуслы салкында да көнетөне эшләтәләр. Алдан-арттан, ян-яннан мылтыклы сакчылар озата бара, бер кая борыла алмыйсың, шунда ук тәгәрә-

теп кыйный башлыйлар. Балаларның өс-башлары юка, үзләре чамасыз авыр эштән тәмам ябыктылар, беттеләр. Шушы хәлдә унике чакрым ачы җилдә кыр буйлап барырга, кыр буйлап кайтырга кирәк, унике сәгать сыртыңа салып кирпеч ташырга кирәк. Моңа үсмер балалар түгел, олылар да түзә алмый, йә юлда, йә кирпеч арасында тәгәрәп үләләр. Һәм бу газаплардан мәңгегә котылалар...

Сажидә бүген бигрәк тә авырлык белән атлый, күтәрмәгә калган чабатасы таеп-таеп китә, өс-башы шыкыраеп каткан. Шуңа күрә аны анасы белән апасы ике яктан гел саклабрак йөртә, үз гәүдәләре белән этеп диярлек алып баралар. Ә баскычка, кирпеч төяп, барыбер ялгыз менәргә кирәк... Һай ул баскычларның биеклеге, һай ул баскычларның тайгаклыгы, куркынычлыгы! Алар кар катыш пычрактан боз булып катканнар, аз гына ялгыш бассаң да, кирпечең-ниең белән аска очуың бар. Берең егылса, арттагылар да ава, өстеңә кирпечең ишелә, башыңны мылтык түтәсе төя. Инде ничә кеше, шулай биектән егылып төшеп, кирпечләр астында калып үлде. Маһинур абыстай һәр көнне дарга менгән кебек менә ул текә баскычлардан, үзеннән дә бигрәк, кызлары өчен курка ул, бигрәк тә Сажидәсе өчен. Шуңа күрә ул аны үз алдына куя, берәр нәрсә булса, ярдәм итә алырмын дип өметләнә.

Әнә Сажидә бүген дә, гыж-гыж сулап, җилкәсенә кирпеч төяп, әнисе алдыннан домна мичен менеп бара. Бер баскыч, ике, ун, егерме. Әле йөзгә хәтле менәсе бар, аннан соң тагы биш текә баскыч, анда инде кирпечләреңне бушатырга да була. Төшкәч тагы шул юл башлана. Бер баскыч, ике, ун, егерме. Бүген Сажидә бигрәк тә авыр сулый, аягын да өстерәп кенә атлый. Ә туктарга ярамый, алар артыннан тезелеп, кирпеч төяп, башкалар менеп килә. Башка коллар атлый. Менә алар баскычның инде яртысына җиттеләр, әле тагы күпме менәсе бар. Ананың күз алдында баласының тишек чабаталары гына тора, бөкерәйгән килеш ул шуларны гына күрә ала. Чабата тишегеннән, кып-кызыл булып, кызының чиләнгән аяклары күренеп тора. Менә Сажидә нигәдер адымын акрынайтты, кирпеч баскан аркасы тагы да бөкрәйде, иелеп килде. Маһинур абыстай кызына нидер булганын сизде, әмма аркасын турайтып карый алмады, аның да җилкәсен авыр кирпеч баскан иде.

— Кызым, акрын гына атла, атла, төшкәч ял итәрбез, — диде ул, туктап калган кызына килеп төртелеп.

— Атлый алмыйм, әни, башым әйләнә, — диде Сажидә, авыр гыжлап.

Арттан килгән Гайшәбикә әнисенә килеп төртелде, аны башкалар ашыктыра башлады. Астан мылтыклы сакчыларның сүгенгәне, ярсып кычкырганы ишетелде, буыла-буыла

этләр өрергә тотынды. Чөнки монда, баскычта, бер минут та туктап торырга ярамый, югыйсә бөтен эш тукталачак иде. Монда эш чылбыр кебек көйләнгән — кирпеч килеп тора, аны өскә ташып торалар, ул кирпечне стенага өя торалар, шулай итеп, домна мичләрен, завод торбаларын, цех диварларын күтәрәләр. Тиздән беренче домна чуен бирергә тиеш, бу турыда инде бөтен ил белә, бөтен ил көтә. Сталин бу хәбәрне көтә. Ә монда аңсыз кулак калдыклары бөтен эшне өзәргә мөмкиннәр. Шуңа күрә эшне өзүчеләрне, эштән туктаучыларны туп-туры төрмә көтә, аннан исә бик азлар гына исән чыга. Моны белгән коллар ничек тә эшне туктатмаска, өстерәлеп булса да ахыргача түзәргә тырышалар.

— Кызым, ничек тә атла, балакаем, күп калмады инде, түз, кызым, — ди ана, җан газабыннан һәм аркасындагы йөгеннән тәмам сыгылып төшеп.

Саҗидә авырлык белән генә кузгала башлый, әмма чабаталарын боздан кубарып ала алмый. Аяк атларга итеп, ул тартылып куя һәм, тигезлеген югалтып, баскыч култыксасына ава. Аркасындагы авыр йөге аны котылгысыз рәвештә аска тарта һәм бала, гөрселдәп, җиргә барып төшә. Өстенә шыбырдап кирпече коела, кемдер кычкыра, кемдер сүгенә, кемдер елап җибәрә. Әмма эшне туктатып булмый, биек баскычны менеп бетермичә, аска төшеп булмый. Маһинур абыстай бу юлны ничек үткәнен, кирпечләрен бушатып, ничек аска атылып төшкәнен хәтерләми. Ул җиргә төшеп җиткәндә, Саҗидә инде җан биреп ята иде... Кызның ачык калган зур күзләрендә домна мичләренең дәһшәтле шәүләсе чайкала. Тишек чабатасыннан ялангач аяклары күренеп тора. Асылгәрәй хәзрәтнең затлы бер баласы, ач далага көчләп китереп ташланган бер былбылы, домна миченә дигән кирпеч астында калып, җан бирә. СССР империясе алып барган бөек төзелешнең бер корбаны була...

Саҗидәне, чана белән баракка алып кайтып, яшерен генә кәфенләп, җеназа укып, Урал ярына алып барып күмделәр. Җир туң, шыкырдап каткан иде, ач ата-ана, балалар аны төне буе чокыдылар, таң алдыннан Саҗидәнең мәетен җиргә тапшырдылар... Төне буе дала ягыннан ач бүреләрнең улавы, җилләрнең җиргә ятып елавы гына ишетелеп торды. Аста, төн булуга карамастан, меңләгән уты, меңләгән колы һәм корбаннары белән бөек төзелеш кайный иде. Домна мичен вакытыннан алда тапшыру өчен тиңе булмаган көрәш бара иде. Татар баласы Саҗидә бу көрәшнең чираттагы бер корбаны булды. Асылгәрәй карт белән Маһинур абыстайның Урал аръягында, Магниткада беренче югалтулары иде...

Ул елны Магниткада, данлыклы комсомол төзелешендә, үлүчеләр саны туучыларга караганда ун тапкыр күбрәк бул-

ды. Бу үлүчеләрнең күпчелеге татарлар, балалар һәм картлар иде. Сөргенгә сөрелгәннәрнең яртысына якыны беренче кышта ук кырылып бетте, аларның саннарын алучы да булмады. Нинди генә авырулардан кырылмады мескен татарлар: тифтан, ачтан, өшеп-катып, эч китү — дизентериядән, дифтериядән, үпкә чиреннән, туберкулездан, кызамыктан, чәчәк авыруыннан, түләмәдән, әллә нинди билгесез авырулардан, эштәге бәхетсез очраклардан, кыйналып һәм җәзаланып җан бирде бөек төзелешкә сөрелгән татарлар. Монда барысы да кеше тизрәк егылып үлсен өчен көйләнгән иде, бигрәк тә яшь балалар һәм эшкә ярамаган картлар төзелеш җитәкчеләренә кирәкми иде. Алар монда артык иде.

Моны халык үзе дә сизенде...

Биредә тагы бераз калсалар, алар барысы да үлеп бетәселәр иде.

Җитәкчелек, максатчан рәвештә, эшкә яраклыларны гына сайлый, калган бөтен кирәкмәс җаннарны кисеп ташлап калдырырга тырыша иде. Ә ул кирәкмәс җаннар кемнәрнеңдер газиз балалары, кадерле ата-аналары, әби-бабалары. Инде картаеп барган шул ук Асылгәрәй хәзрәт белән Маһинур абыстай, әлегә эшкә ярамаган Солтанхәким белән Мәрзия. Калганнарының төзелеш каннарын сыга, Гайшәбикәне, Гыйлемгәрәйне, Сәгыйтьне ат урынына җигә, хәзергә ата белән ананы да һәр көн эшкә куа. Әмма алга таба алар да төзелеш җитәкчеләре өчен кирәкмәс кашыкка әйләнәчәкләр, шуңа күрә ил өчен аларның булганнан булмаганнары артык.

Моны Асылгәрәй карт белән Маһинур абыстай үзләре дә сизенәләр...

Халык арасында чыш-пыш, төрле сөйләшүләр бара...

Һәм кемнәндер беренче тапкыр «качу» дигән сүз чыкты...

Әйе, боларның берәм-берәм үтереп бетергәннәрен көтеп ятмаска, бу Алла каргаган урыннан кая булса да китәргә, качарга кирәк иде. Әмма кая? Һәм ничек итеп? Бөтен тирәякта мылтыклы сакчылар, итәк тулы бала, авылда да беркем көтеп тормый, тотып алып, кире җибәрүләре дә бар. Әмма алга таба монда калу үлем дигән сүз. Ачтан, өшеп, кыйналып, кешелектән чыгып бетеп, мәсхәрәле рәвештә үлү дигән сүз. Монда адәм баласы эттән дә түбән хәлдә, үлгәч кабере дә уртак чокырда, йә булмаса мәете ачык кырда аунап кала. Сөякләре завод нигезенә түшәлә. Качу исә бераз булса да ирекле яшәп алу, исән калуга бер өмет, хәрәкәт дигән сүз.

Күпләр алга таба бары тик качу уе белән генә яши башладылар...

Качарга!

Әйе, әйе, моннан качарга, туган якларга кайтып егылырга,

үз җиреңнең чирәмен булса да ашап яшәргә, саф суларын яңадан эчәргә, яңадан кеше булып яшәргә! Илдә чыпчык үлмәс, бөтенесен дә кире кумаслар, балалар булса да яшеренеп исән калыр, кеше булып калыр...

Качарга!

Бары тик качарга...

Кызлары Саҗидә шулай фаҗигале төстә үлгәннән соң, Асылгәрәй карт та качу турында уйлый башлады, Маһинур абыстай да гел шул турыда сүз кузгатты. Дөресрәге, моннан качарга кирәклек турында башлап шушы гаилә татарларга сүз катып карады, карт муллалар белән киңәште. Барысы да качарга кирәклек белән килештеләр, юлларын, әмәлләрен эзли, өйрәнә башладылар. Ни әйтсәң дә, кыш көне бу мөмкин хәл түгел иде... Урал таулары аша китсәң, анда билдән кар, аяк астында ашарга берни юк, далага чыксаң, уч төбендә кебек күренәсең, ач бүреләргә азык булуың бар... Бөтен тирәякта, тавында-даласында мылтыклы сакчылар йөргәнен дә онытмаска кирәк... Димәк, язны, җәй башын көтәргә кирәк, үлән чыксын, агачлар яфрак ярып, арасына кереп качарлык булсын. Инде ничек тә бу авыр кышны исән чыгарга кирәк, язга хәтле ничек тә түзәргә, түзәргә...

Кешеләрдә өмет барлыкка килде...

Татарлар качу хыялы белән яши башладылар...

Асылгәрәй карт һәм тагы берничә ир-ат, сакчыларга сиздерми генә, тирә-якны җентекләп өйрәнә, күзәтә, сораштыра башладылар. Баксаң, моннан качып киткәләүчеләр булгалаган икән инде, аларның кайберләрен тотып төрмәгә япканнар, кайберләре киткән килеш юкка чыккан, яңадан монда әйләнеп кайтмаган. Алар, бәлки, туган якларында урнашып калганнардыр, бәлки, казах-кыргыз далаларында качып йөриләрдер. Ә бәлки инде, кайберләре дөньяда да юктыр. Ни булса да, кешеләр кача һәм бер өлеше яңадан монда кайтмый иде... Димәк, барысын да тотып бетерә алмыйлар, димәк, котылырга өмет бар? Илгә кайтып җитә алса, Асылгәрәй карт суд юллары аша булса да үзенең гаепсезгә сөрелүен исбат итә алыр иде, юк икән, балаларын булса да шунда урнаштырып калдырыр иде... Ул хәзер бары тик балалары турында гына уйлый иде, аларны мондый түбәнлектә һәм газапта яшәтергә аның хакы юк иде...

Шушы уй Асылгәрәй картның башына тәмам кереп утырды һәм ул язга хәтле әкренләп хәстәрен күрә башлады. Үз авызларыннан өзеп, Маһинур абыстай белән азлап-азлап сохари киптерә башладылар, юлга дигән өс-башларын, аяк киемнәрен алдан әзерләп куйдылар, качу юлларын җентекләп өйрәнделәр.

Качарга! Бары тик качарга!

Илгә кайтырга, Зәйтуганга кайтып егылырга, шунда туфрак булырга...

Бу уйларыннан аларны хәзер бары тик үлем генә туктата ала иде...

* * *

Адәм балаларының мондый салкын һәм рәхимсез кышны күргәннәре юк иде әле.

Себер ягыннан өшеткеч җил исә, ул хәтта җир өстендәге карны да тотмый, һәр нәрсәне каткан бозга әйләндерә. Салкынлык бер дә утыз градустан кимеми, утыз биш, хәтта кырык градуска хәтле җиткән төннәр дә була... Үлүчеләрне хәзер беркем исәпкә алып тормый, ә тереләрне, җан өшеткеч салкын булуга карамастан, һәр көн эшкә куалар. Инде качасы комсомоллар, ирекле активистлар качып бетте, төзелештә төп эшче көч булып төрмә тоткыннары һәм сөрелгән ирексезләр генә торып калды. Эш хәтта төннәрен дә бара, чөнки җитәкчелек беренче чуен кою мичен эшләтеп җибәрергә әзерләнә. Америка белгечләре исә моңа кискен каршы, чөнки кыш көне, бигрәк тә мондый каты салкыннарда, домна мичен җибәрергә ярамый дип баралар. Әмма Магнитка төзелеше җитәкчеләре, партия, НКВД моның белән килешми, алар уенча, совет халкы җиңә алмаган авырлыклар юк. Шуңа күрә халыкны, көне-төне чыбыркылап, зәмһәрир салкында эшкә куалар. Инде бөтен кышкы дала кыймылдаучы, хәрәкәтләнүче коллар белән тулган.

Әнә алар — Магниткадагы татар коллары...

Кемдер тачкага ком төяп йөгерә, кемдер — вак таш, кемдер су биреп тора, кемдер бетон болгата...

Кемдер әзер бетонны, тачкаларга төяп, төзелешкә ташый, кемдер аны көрәк белән махсус билгеләнгән урыннарга бушата...

Кемдер кирпеч суга, кемдер, җилкәсенә кирпеч салынган әрҗәләрне асып, баскычлар буйлап өскә үрмәли, кемдер ул кирпечне стена итеп өя...

Кемдер, туң җирне чокып, тирән котлованнар казый, кемдер аннан чыккан балчыкны тачкалар белән өскә ташый, кемдер таш чыгара, кемдер нигез сала, кемдер инде түбә яба...

Күп кеше чабатадан, ертык бишмәтләрдән, өсләреннән пар чыгып тора, арган йөзләренә кирпеч һәм баз тузаны кунган. Монда эшләрдәй картлар да, үсмер балалар да, ирләр дә, хатыннар да бар. Бар дөнья гүләп, тетрәп, кайнап тора. Монда чабаталы татарлар Магнитка салалар...

Ниһаять, булды...

Шартлап торган гыйнвар салкынында беренче домна ми-

чен эшләтеп җибәрергә әзерләнделәр. Әмма барысы да нәкъ Америка инженерлары кисәткәнчә килеп чыкты — туң җир ярылып китеп, мич ут урынына су белән тулды. Бу көтелмәгән аварияне бетерү өчен, халыкны билдән бозлы суга куып керттеләр, чуен коеларын тиз арада судан арындырырга, җирнең ул өлешен яңадан бетонларга боердылар... Качмый калган берничә комсомолец, капитализмны җиңәргә өндәп, бугаз ертты, ә бозлы суга тоткын татарларны ыргыттылар... Җир астыннан бәреп чыккан су белән көрәш егерме сәгать барды һәм күпләрнең башына җитте. Күпләр шунда мәңгегә ятып калды, башта каткан бозга әйләнде, аннан ялкын булып домна мичләреннән очты...

Икенче көнне иртәнге сәгать сигездә беренче чуен кою мичен ачу тантанасы булды. Әмма күп татарлар анда катнаша алмадылар, тәүлек буе бозлы суда эшләгәннән соң, алар, уттай янып, үлем көтеп яталар иде. Бәхеткә, Асылгәрәй карт үзе дә, аның гаиләсе дә бу бозлы җәһәннәмгә эләкмичә кала, әмма көн дә туң җирне казу аларны да тәмам эштән чыгарган, бетергән иде...

Ниһаять, меңнәрчә тоткыннарны утка һәм суга салып газаплый торгач, беренче номерлы домна миче беренче чуенын бирә. Шунда ук бу хакта Мәскәүгә телеграмма-молния китә. Җавап итеп Сталинның да котлау телеграммасы килә һәм ул 1932 елда тагы дүрт чуен кою мичен эшләтеп җибәрергә әмер бирә. Әмма моны башкарып чыгу өчен тагы дистә мең эшче көчләр кирәклеген барысы да аңлый. Ә аларны кайдан алырга? Сөрелеп килүчеләрнең инде яртысы үлеп бетте, калганнары да тере мәет хәлендә. Димәк, төзелешне дәвам итү өчен яңа көчләр кирәк, ә аларны бары тик авыллардан һәм бары тик шушы көчләү юлы белән генә җыярга була. Сталин инде моның юлларын белә...

Һәм Урал артына, Магниткага тагы вагон-вагон әсирләр, тоткыннар, илдән сөрелгән татарлар агыла башлый. Хәлле булган өчен кулак дип сөрелгәннәр, дин әһелләре, татар зыялылары — Магнитка барысын да утлы авызына йота гына бара. Һәр айда биргә унышар-уникешәр мең татарны китереп ташлыйлар. 1932 елның башына аларның исән калганнары һәм исәптә булганнары утыз ике мең дип теркәлгән, әмма бу сан ике-өч тапкыр күбрәк була. Ул чорда Магнитка төзелешендә йөз мең чамасы әсир татар эшләп, шуның бер өлеше гел үлә торган, алар урынына яңаларын куып китерә торганнар. Әсир татарлар өчен, чәнечкеле тимерчыбыклар белән уратып алып, дүрт махсус бистә ачканнар, аларны, сәяси яктан матурлап, «трудпоселок»лар дип йөрткәннәр. Йөзләгән баракка сыймаган меңләгән татар әсире, землянкалар төзеп, җир астында яшәргә мәҗбүр булган...

Шулай итеп, СССР империясенең гигант төзелеше хакына татар халкының асыл, затлы балаларын җир асларына куып кертәләр, аларны бетле, бозлы баракларда яшәргә мәҗбүр итәләр. Милләтнең иң укымышлы катламын тирән котлован-базларга, ут чәчеп торган домна мичләренә, бозлы суларга ыргыталар, алар көче белән буш далада металлургия комбинаты торгызалар. Әмма котлауларны, рәхмәт сүзен татарлар түгел, башкалар ишетә, Магнитканы чабаталы әсир татарлар түгел, батыр комсомоллар төзегән, дип, тарихка язып калдыралар. Һәм бу ялган бүген дә дәвам итә...

Беренче домна миче чуен бирә башлагач, Магнитстройның ул вакыттагы җитәкчесе Гугель һәм горком секретаре Карклиннар бөтен дөньядан котлау арты котлау кабул итәләр. Сталинның үзеннән, Кировтан, Блюхердан, Горькийдан, чит ил коммунистларыннан... КПСС Үзәк Комитеты Магниткада социалистик хезмәтнең яңа алымнарын булдыру һәм биредә яңа кеше тәрбияләү буенча махсус карар кабул итә. Балчыктан әвәләнгән теге заман кешесен тимер рудасы кебек домна мичләренә, ягъни социалистик хезмәт казанына салып кайнатып, аннан замананың чуен кешесен ясау максаты куя ил һәм аның җитәкчеләре. Бу чуен казанына сөргенгә сөрелгән бөтен татарлар да салып кайнатылырга тиеш булалар, шул исәптән Асылгәрәй хәзрәтнең асыл нәселе, гаиләсе дә...

Шушы «бөек» максатны тормышка ашыру өчен, Магниткага Мәскәүдән идеология фронты эмиссарлары — язучылар, журналистлар агыла башлый, зур шәхесләр килә. Ул заманда биредә язучылар Аркадий Гайдар, Валентин Катаев, Демьян Бедный, Федор Гладков һәм башка язучылар булып китәләр, бөек төзелеш турында тимер китаплар, таштай очерклар язып калдыралар. Әмма алар берсе дә көн дә яшәү белән үлем арасында тартышкан татар тоткыннарын күрмиләр, аларның тиңсез хезмәтенә тиешле бәяне бирмиләр. Биредә шулай ук Ворошилов, Орджоникидзе кебек танылган шәхесләр дә була, ә язучы Максим Горький исә Магнитка төзүчеләре белән даими элемтәдә тора... Горький бу төзелештән бик дәртләнә, аны ил өчен иң зур казаныш дип исәпли, Магнитканың һәр көнен язып бару өчен, җирле тарихчыларга күрсәтмәләр бирә. Әмма бу шәхесләр Магниткада чуен-тимердән башка берни күрмиләр, биредә, нигездә, бер хокуксыз тоткыннар эшләгәнен, аларның үлем хәлендә яшәүләрен белмиләр яки белмәмешкә салыналар. Әнә бит Максим Горький да Мәскәүдән торып ничек дәртләндерә, өйрәтә Магниткадагы партия идеологларын...

«...Изменяется не только «кора» огромной площадки у горы Магнитной, но в этой работе социалистически перевос-

питываются тысячи колхозников, приехавших на стройку, — дип яза ул Магнитка җитәкчеләренә 1932 елда. — История вашего строительства — дело не местного значения, а огромной политической и воспитательной важности для всего Союза Советов...»

Әйе, чуен казаннарында кайнап, яңадан тәрбияләнергә тиешле кешеләр, соңыннан гомер буе шушында кол булып эшләргә тиешле халык ул — татарлар була...

Мәккә-Мәдинәләрдә булган, Төркия-Мисырларда белем алган Асылгәрәй хәзрәт тә шушы социализм казанында кайнарга тиеш була...

* * *

Бүген, беренче домна мичен эшләтеп җибәрү уңаеннан, халыкка бераз ял бирделәр. Иртәнге якта бар кешене мәйданга кудылар, анда, кызыл байраклар болгап, җиз торбалар уйнатып, кайнар нотыклар сөйләп, мичне өрдереп җибәрделәр. Мичтә кайнар һава мең градуска җитә язды, формаларга, ут телләре булып, кайнар металл агып төште. Меңнәрнең газаплы күз яшьләре булып кайнар чуен агып төште. Аннан калай әтәч комсомоллар бәйрәм итә, бер-берләрен котлый башладылар, урыслар чүгә-чүгә, сызгыра-сызгыра биергә тотындылар, татарлар тизрәк баракларга кайтып китү ягын карадылар. Анда, нәрсә әйтсәң дә, урамга караганда ышыграк иде, йөзләгән кеше тыны белән җылытып, бараклар катып үлмәслек хәлгә килгән иде...

Озын, шыксыз барак бүген дә үз тормышы белән яшәп ята...

Һәркем корт кебек үз почмагында кайнаша, һәр милләт үзенчә аерымрак урнашкан. Әнә баракның бер башында урыслар өелешкән, алар бәйрәм хөрмәтенә каяндыр самогон табып алганнар, хәзер аяк тибеп шуны эчәләр. Димәк, бүген сугышсыз булмый икән. Урыслар яшәгән баштан кычкырышкан, талашкан, җырлаган тавышлар ишетелә. Чуваш-мари бу эшкә кушылмый, чөнки кушылсалар, гел аларны кыйнау белән бетә. Ә татарлар, гомумән, аерым тормыш белән яши. Алар гел бергә, авыл-авыл, район-район булып урнашканнар, исән калу өчен бергәләп тырнашалар. Кеше үлсә дә, кеше туса да, татар бергә кичерә, бергә күтәрә. Монда әле һаман, туган яклардагы кебек, төп сүзне олылар әйтә, яшьләр аларның киңәшен тота. Асылгәрәй хәзрәт баракта үзенә күрә татарларның бер җитәкчесе кебек, халыкның бөтен эшләрен оештырып, күзәтеп тора.

Менә бүген дә аның янына ак сакаллы картлар җыелган. Сөйләшәләр, киңәшәләр...

Заманында Төркияләрдә, Мисырда, Мәккә-Мәдинәләрдә, Бохараларда бергәләп укып йөргән акыл ияләре, милләтнең бик билгеле, данлыклы кешеләре. Әнә сиксән ике яшьлек Аллаһъяр карт, аның йөзенә карасаң, күз чагыла, шушы каралыкта да ул нурын җуймаган. Аллаһъяр хәзрәт атаклы Мәңгәр авылыннан, аны ишанлыкта гаепләп кулга алганнар, бөтен нәселе белән бирегә сөргәннәр. Килгәч тә аның карчыгы үлде, хәзрәт, Урал елгасы ярына алып чыгып, аны үзе юды, үзе кәфенләде, үзе җирләде. Әнә сиксән яшьлек Шакир хәзрәт, ул Арча ягыннан, Арпаяз дигән авылдан. Бирегә килгәч, аның аяклары йөрми башлады, ул, түбәтәен киеп, көннәр буе сәке читендә утыра. Ул соңгы вакытта колакка да бераз катыланды, шуңа күрә кеше белән бик аралашмый, үзалдына мөнәҗәт әйтеп, моңланып утыруын белә. Шакир хәзрәт мөнәҗәт әйткән җирдә гел хатын-кыз була, алар, аны тыңлап, тын гына елыйлар. Бүген Шакир хәзрәт аеруча моңая, сукыраеп барган күзләреннән яшьләре мөлдерәп-мөлдерәп агып төшә. Бүген ул үзе турында чыгарган мөнәҗәтен әйтә:

Тарих мең дә тугыз йөз дә
Утыз беренче елларда
Аердылар илләремнән,
Сабыр бирсен үзе Алла…

Шушыдыр бәнем язганым,
Илемдин башым алганым.
Еласам да чара юктыр,
Күрермез хакның язганын…

Сак белән Соктай тилмереп
Ниләр күрербез икән?
Сөргеннәргә сөргән җирдә
Әрәм булырбыз микән?

Хатын-кыз, Шакир хәзрәтне тыңлап, мышык-мышык елый…

Авырлыктан акылына җиңеллек килгән Әһлиулла карт, аркаларыннан кагып, аларны юатып йөри:

— Атлар җигелгән, еламагыз, хәзер юлга чыгабыз, — ди…

Әнә сәке саен Саба муллалары тезелеп киткән, әйтерсең лә бөтен районнары белән монда куылганнар… Әнә Сабаның үзеннән атаклы мулла Мөбарәкша хәзрәт. Әнә Иләбәр авылыннан Хәлил хәзрәт, Килдебәктән Сәгыйть мулла, Туктардан Шәмсемөхәммәт хәзрәт, Эзмә авылыннан Госман мулла, Сатыштан — атаклы Бигәнәй ишанының улы Габдрахман хәзрәт һәм башкалар, һәм башкалар. Әнә тагы иң зур хәзрәт — Әхсән мулла, Габделәхәт хәзрәт, Гариф мулла. Болар — Коръәнне яттан белүче зур гыйлем ияләре, шушы шартларда да яшереп намаз укыйлар, ураза тоталар, шәригатьчә яшәргә тырышалар. Алар башкача яши белми дә.

Ак сакаллы, татарлыклары кычкырып торган түбәтәйле бу картлардан ничек кенә көлмиләр бирелә урыслар! Караңгыда ялгыз бәдрәфкә чыксалар, аларның кулларыннан комганнарын бәреп төшерәләр, баракта аяк киемнәренә пес итеп куялар, кеше югында, башларындагы түбәтәйләрен, бәреп төшереп, идән буйлап типкәләп йөртәләр. Бу хәлләр күбрәк көндез, бөтен кеше эшкә киткәч була, урыс балалары, исерек кавем бирегә сөрелгән өчен җитәкчеләрдән ала алмаган кара үчен шушы татар картларыннан ала.

Әмма татар картлары өчен иң авыры, иң зур хурлык әле бу түгел, ә башкасы. Завод котлованнарын казырга көчләре җитмәгән бу татар картларын комендатура иң пычрак эшкә куя — аларны, мулла бабайларны, урамдагы гомумбәдрәфләрне чистартырга мәҗбүр итәләр. Алар башта бу нәҗесне чиләкләр белән мичкәләргә тутырырга тиеш булалар, аннан, шул арбаларга ат урынына җигелеп, аны ун-унике чакрымдагы далага ташыйлар. Һәр көн саен шушы хәл. Йә син котлован казырга барасың, йә бук түгәсең. Бу хурлыктан сине үлем генә коткара ала. Бу эшләрнең барысы белән дә комендант Шишкалов, бригадир Коновалов, махсус идарәнең белгече Эльтерманнар җитәкчелек итә. Урыс белән яһүди, дини татар картларын шушы рәвешле мыскыллап, үзләренә тәм табалар, күрәсең…

Хатын-кызларның исә үзләренә бер бәла…

Бөтен бараклар беткә батып, халык тифтан кырыла башлагач, исән калганнарны мәҗбүриләп мунчага куа башладылар. Мунча дисәң, хәтере калыр — озын баракның бер башыннан куып кертәләр, икенче башыннан пешекләп куып чыгаралар. Мунчада йә җылы су, йә салкын су булмый, кеше аннан пычранып кына чыга. Киемнәреңне кергәндә үк салдырып алып калып, аны кыздыру камераларына парда өтәләргә тотып аталар, хлор белән бутыйлар. Чыкканда, кеше үз киемнәрен таба алмый, булган кадәресен тарткалап-йолыккалап бетерәләр. Кыш көннәрендә хатын-кызлар мунчадан ярым шәрә баракларга кайтырга мәҗбүр булалар, күбесе соңыннан авырып егыла, гүр иясе була…

Әмма бу мунчада хатын-кыз өчен иң газаплысы — бет бетерәбез дип, мунчада аларның озын чәч толымнарын төбеннән шартлатып кисеп алалар, башларына агулы су сиптерәләр. Шушы агулы су агып кереп, берничә татар хатынының күзләре сукырайды, гомергә гарип калдылар. Аннан соң калган чәчләрен машинка белән кырып алалар. Шуңа күрә Маһинур абыстай кызларының башына бет кертмәскә тырышты, кар эретеп булса да, аларның озын чәчләрен селтәләп үзе юды. Ә баракта күп хатын-кызларның чәчләре кырып алынган, яулык астында булганга гына күренми иде…

Ирләр, әлбәттә, бу хәлләрне белә һәм гаиләләрен яклый алмаганга тәмам гаҗиз калганнар иде...

Инде нишләргә, ничек исән калырга бу җәһәннәм базында?

Ничек кеше булып калырга, иманны җуймаска?

Шушында берәм-берәм үлеп-кырылып бетәргәме, әллә берәр чарасын күреп караргамы? Монда аларны кешегә санаучы юк, монда аларның егылып үлгәнче эшләүләре генә кирәк. Юньле кеше үзенең хайванына да яхшырак карый — тамагы туйганчы ашата, судан өзми, җылы абзарда тота, юкка-барга сукмый, ормый. Ә монда бер телем ипи хакына унсигезәр сәгать иң кара, иң авыр эшләрдә эшләргә кирәк. Адәм чыдый алмаслык түбәнлектә яшәргә кирәк. Бу балаларның исән калганы да монда нәрсә күреп үсә? Урыс булган бөтен җирдә эчү, сүгенү, талау, сугыш, көчләү, үтереш. Һәм беркемгә зарлана алмыйсың, чөнки син — хокуксыз, чөнки өстә утыручылар үзләре дә шул ук кавем вәкилләре...

Шушы хәлләргә чыдый алмыйча, кешеләр кача...

Берәм-берәм, бөтен гаиләләре белән, кем кая туры килә — шунда...

Магнитка дигән мәхшәрдән генә ерак булсын...

Асылгәрәй карт инде белеште, хәзер шуны башкалар белән дә уртаклаша, иң яхшысы — җәй көне Урал аша качу икән. Чөнки аннан тота алмаячаклар. Ә дала ягына качсаң, син уч төбендәге кебек ялтырап ятасың. Бөтен тирә-якта аларның сакчылары, этләре, каланчалары икәнлекне дә онытмаска кирәк. Далада ук талатып үтерерләр, монда кайтарып та тормаслар. Башка картлар да шул ук фикердә, яшьләрне дә шуңа әзерлиләр...

Качарга кирәк, качарга...

Язга чыгып, агачлар яфрак яру белән, җәй башында тәвәккәлләргә кирәк. Аларның кулында бер документ та юк, шуңа күрә поездлар белән китү авыр булачак, чөнки анда тикшерәләр. Хатын-кызлар, бала-чагалар шул юл белән дә китәргә мөмкиннәр, әмма Магнитка вокзалында утыру турында сүз дә була алмый, монда иң көчле тикшерү. Димәк, алдагы станцияләргә җәяү чыгып, шулай утыра алсаң гына. Ә ирләргә барыбер башка юллар белән качу кулайрак булачак, кеше күзенә күренмичә, таулар аша, Урал аша...

Татар картлары әкрен генә шулай киңәшеп утыралар, ә теге башта урыслар ду килеп сугышырга ук тотындылар. Алар гел шулай — бәйрәм дип башлыйлар да сугышып тәмамлыйлар. Менә хәзер дә һавага табак-савытлар, мендәрләр оча башлады, балалар еларга, хатын-кызлар чәрелдәргә тотынды, исерек ир-атларның үкергәннәре, сүгенгәннәре яңгырап торды. Менә алар, барысын ватып-җимереп, сугыша-

сугыша, барак уртасына хәтле тәгәрәп килеп җиттеләр, җыелышып утырган татар картларына килеп бәрелделәр. Картлар, куркышып, бер читкә тайпылдылар, аяксыз Шакир бабай гына сәке читендә утырып калды. Ул юньләп ишетми дә, күрми дә, шуңа күрә баракта ни булганын абайламыйча калган иде. Җитмәсә, дивана Әһлиулла карт килгән дә, аңа һаман җырларга куша, гүләп торган баракта алар икесе мөнәҗәт әйтүләрен дәвам итәләр...

Әй Ходаем, инде сәндин нинди теләкләр телим?
Гомер иткән илләремә кайтарсаңчы, дип сорыйм...

Туган илдән чыгып киткәч, карадым күмелгәнче.
Туган илне онытмамын, гүрләргә куелганчы...

Ул арада исерек төркем, сугыша-сугыша, инде алар турына килеп җиткән иде. Бу татарларның аларның юллары өстендә кузгалмыйча утыруларын урыслар үзләренчә аңладылар, «Татарская морда!» дип, дивана картлар өстенә ыргылдылар. Асылгәрәй хәзрәт, ике арага кереп, картларны якларга тырышып карады, аның үзен дә барак стенасына китереп сыладылар. Аны яклап башка татарлар кузгалды, инде кемнең кем белән тартышканын аңларлык түгел иде. Ул арада исерек төркем Шакирҗан карт белән Әһлиулла бабайны өереп алдылар да боз булып каткан барак ишегеннән кышкы урамга алып томырдылар. Бу хәлләрдән Миргалим исемле картның өянәк чире кузгалды, ул эпилепсия чиреннән идәнгә барып төшеп, тартыша, гырылдый башлады. Исерек урыслар аны да, аякларыннан сөйрәп, урамга чыгарып аттылар. Аннан, берни булмагандай, барак ишегенә аркылы басып, тагы кочаклашып самогон эчә башладылар. Алар шактый вакыт баракка беркемне кертмәделәр дә, чыгармадылар да. Кышкы салкынга чыгарып аткан картларны алып керергә беркемгә ирек бирмәделәр, ишек яныннан чөеп кенә аттылар. Исерек урысларны көч-хәл белән аралап урамга чыкканда, авыру өч татар карты инде шыкыраеп каткан, ничек барып төшсәләр, шулай җан биргәннәр иде.

Комендант Шишкалов, бригадир Коновалов бу эшне куертып тормадылар, өшеп үлүне картларның үзләренә сылтап калдырдылар да бу хакта сүзне туктаттылар. Имеш, бу татар картлары хаҗәтләрен үтәргә урамга чыкканнар да керә алмыйча өшеп үлгәннәр. Монда андый хәлләр еш булып торганга, картларның үлемен тикшереп тә тормадылар.

Татарлар бу картларга яшерен җеназа укып, бозлы далага илтеп күмделәр. Аерым кабер казырлык хәлләре булмагач, туң җирне тырнаштырып, өчесен бер кабергә салып кайттылар...

Ә Магнитка әле кичкә кадәр бәйрәм итте.

Бүген биредә беренче домна миче эшли башлаган иде.

Бу хакта Сталин үзе котлау телеграммасы җибәргән иде.

Бүген өшеп үлгән өч татар картын бозлы далага күмеп кайтканнар иде.

Аларның җаннары Урал таулары аша туган якларына кайтып бара иде.

Бәхилләшү авазы булып барак эчендә һаман Шакирҗан картның моңлы тавышы яңгырап тора кебек иде...

Бәнем эчемдәге хәсрәт язып һич бетәчәк түгел,
Бәнем башым китте инде, кош очып җитәчәк түгел...

Берәр кайтып күрерменме печән чапкан тугайларым,
Эчем-бәгъремне шул өзә: еглап калды туганнарым...

Хәлемне кем беләчәктер, гамемне кем сорачактыр,
Бу гарип баш ят илләрдә, чит илләрдә үләчәктер...

* * *

Барак халкы май аен чакка-көчкә көтеп алды...

Ул кышны барак халкы өч төрле авырудан: тифтан, бизгәктән, үпкә чиреннән кырылды. Ишле гаиләләр яртылаш кына калды, карт-коры үлеп бетә язды, инде тәмам бетеренгән яшьләргә дә чират җитте.

Урал кышы шулкадәр озын һәм салкын булды, инде ул бу якларга мәңге китмәскә килгән кебек тоела башлады...

Кешеләр күк йөзендә кояш күренүен тилмереп көтә башладылар, ә ул апрель аенда да атналар буе болыт астыннан чыкмады.

Туң җир һаман эремәде, тәннәргә һаман җылы кермәде, чыкмаган җанда өмет бетә башлады.

Боз астыннан җир күренсә, үлән чыгар, ашарга ризык булыр дип өметләнде күпләр. Әмма яз бу мескен кешеләргә үз авырлыкларын алып килде. Язга чыгу белән, алар өчен эш тагы да артты, төзелештәге көнлек эшләреннән соң кешеләрне далага чирәм җир казырга куа башладылар. МОС, ШОС дип аталган бу совхоз җирләре алар тора торган урыннан ун-унике чакрымнарда булып, һәр кич эштән соң бу әсирләрне шунда җир казырга алып китәләр иде. Һәр кешегә норма бирелгән — ике йөз квадрат метр җир казу. Һәркем караңгыга хәтле ач килеш шунда казырга мәҗбүр, моның да мылтыклы сакчылар карап торып эшләтә. Гомер күрәк, сука күрмәгән чирәм җир шыкыраеп каткан, аны кисәкләп чукый-чукый җаннар чыга. Үз нормаңны казып бетермичә, баракка кайтармыйлар, ашарга ипи өлешеңне бирми-

ләр, шунда ачтан, хәлсезлектән егылып үләсең. Биредә көрәккә таянган килеш үлеп калучылар шактый булды. Шуңа күрә кешеләр бу җир өлешләрен ничек тә ерып чыгарга тырышалар, бер-берләренә булышып, эшләп бетерәләр.

Далада җемелдәп чыгып килгән яшел чирәм аларны Магнит тавыннан да болайрак тарта, әсир итә иде. Кешеләр, үлән күренү белән, далага ябырылдылар, чыккан берен тамырыннан ашап бардылар. Алар хәтта биредәге мал-туарга, хайваннарга да үлән калдырмадылар, чөнки алар инде үзләре хайванга әйләнеп баралар иде. Җирдә нәрсә кыймылдый, нәрсә үсә — мескен әсирләр барысын да авызга озаталар, бигрәк тә балаларны берни белән тыеп булмый, биредә хәзер барысына да ачлык хуҗа иде. Кешеләр җир казырга бөтен гаиләләре белән баралар, кечкенә балалар кара төнгә хәтле мүкәләп үлән ашый, ата-аналары чирәм җир күтәрә иде.

Бүген эштән соң да Асылгәрәй хәзрәтнең бөтен гаиләсен далага, җир казырга кудылар. Көрәк тотып эшләрлек биш җан, һәр кешегә икешәр сутыйдан, гаилә һәр кичтә ун сутый каткан җирне казырга тиеш. Көне буе төзелештә җир казыган, кирпеч ташыган ач кешеләр өчен бу бик авыр эш. Шуңа күрә Солтанхәким белән Мәрзия дә монда, караңгы тәмам төшкәнче, җирдән яшел үлән җыялар. Төнлә исә Маһинур абыстай аннан кысыр аш пешерә, иртә белән шуны ашап, эшкә китәләр...

Инде эңгер-меңгер төшеп килә, ә казыйсы җирнең әле очы-кырые күренми. Асылгәрәй карт, үз өлешен бетергәч, хатыны белән кече улы Сәгыйтькә дә булыша, чөнки алар бигрәк бетеренгән, көрәк тотарлык та хәлләре юк. Олы балалары Гыйлемгәрәй белән Гайшәбикә әле нык күренә, аларның инде буыннары ныгыган, ә Сәгыйть шактый зәгыйфь. Ул кышны да бик авырлык белән чыкты, берничә тапкыр үлемнән калды, тифны үткәрде, үпкәләре белән бик интекте. Инде язга чыккач, ничек тә аякка бастырасы иде бу баланы, чөнки бу хәлендә аңа Урал таулары аша качу җиңел булмас...

Качу уе хәзер аларның башыннан чыкканы юк.

Инде яз җитте, җәйгә керергә торалар, димәк, тәвәккәлләр вакыт та җитә. Гаиләдәгеләр инде барысы да бу хакта белә, шул өмет белән генә яши, шуңа гына әзерләнә. Хәзер аларның берсенә дә авырырга, имгәнергә ярамый, бөтен көчне ерак сәфәргә тупларга кирәк, юл өчен анысын-монысын әзерләргә, ризык тупларга. Хәзер бөтен гаилә шушы максатка эшли, шул хыял белән яши. Баракта күп татарлар качарга әзерләнә, аяк асларының бераз киптерүен, ашарга үлән чыгуын гына көтәләр...

Асылгәрәй карт, билен турайтып, тирә-якка карады...

Эңгер-меңгер вакыт, бөтен тирә-якта тоташ дала җәелеп ята...

Инде шактый соң булуга карамастан, югарыда козгын кошлар бөтерелә, мәет көтәләр. Биредә бөтен дала кеше сөякләре белән тулган, кышын кем кайда егылса, шунда ятып калган. Кар киткәч, барысы да актарылып өскә чыккан... Инде Алла шундый үлемнән сакласын, козгыннарга азык булырга язмасын. Монда хәзер исән калуга бернинди өмет юк, йогышлы авыруларны берничек тыя алмыйлар, гомер булмаган тиф, ваба, түләмә чирләре кешеләрне чалгы кебек чаба. Кешеләрнең бөтен өметләре бу үлем үзәненнән качуда, качуда, качуда...

Җаек суының теге ягында, күгәреп, күккә тиярлек булып Урал таулары күренеп тора. Ирек сөюче ирләрне ул үзенә сыендырырга тиеш. Ул тауларның аргы ягында инде туган як — Уфа, Бөгелмә, Шөгер. Бер караганда, якын гына да кебек, әнә генә бит, болытлар да шул якка таба агалар. Ә икенче караганда, барып җитә торган түгел, бигрәк тә — җәяүле кешегә. Асылгәрәй карт инде барысын да җентекләп белеште — Урал тауларында гына да йөз илле чакрымга сузылган кырык сырт үтәргә кирәк икән. Кырык тау түбәсе, кырык үзән, кырык елга, кырык кыр дигән сүз. Анда аюы һәм бүресе дә, ерткыч селәүсен-рысе да, чагар еланнары, козгын-бөркетләре дә бар икән. Хәтта кайбер тау куышларында кеше ашый торган кыргый кешеләр яшәп ятуын да әйттеләр. Менә шуларны исән-имин үтеп, туган якларга кайтып егылырга кирәк. Бөтен гаилә белән, кечкенә балалар белән. Була торган эшме бу? Үлем юлына җыеп алып чыкмыйммы ул аларны? Ә монда калу үлем түгелмени? Баракта ярты халык кырылып бетте бит инде, әле кыш көне генә качабыз, дип сөйләшеп утырган татарларның күбесе юк инде. Авылдан куылганнарына бер ел тулар-тулмас хәзрәт үзе дә алмадай ике баласын югалтты, калганнары да яшәү белән үлем арасында...

Асылгәрәй карт кишәрлекнең төрле башында кыймылдаган балаларына карады. Алар берсеннән-берсе ябык, хәлсез иде. Кулларындагы көрәкне чак күтәрәләр, әйтерсең лә аңа потлы гер асылган... Мәрзия белән Солтанхәким һаман үлән эзли, үлән җыя, ачлыкка түзә алмыйча, яшел чирәмне тизрәк авызларына озаталар. Әнә Сәгыйть тә, казый торган җиреннән туктап, үлән өзәргә иелгән, ачлыкка чыдый алмыйча, чирәм ашарга тотынган. Тик нигә һаман кузгалмый соң ул, тезләнгән дә көрәгенә башын терәп катып калган. Әллә хәле тагы начарланып киткәнме баланың, әллә терелеп бетмичә өзлеккәнме?

Асылгәрәй карт, эшен ташлап, ашыгып улы янына килде...

Ул тизрәк аның янына җиргә тезләнде һәм малайның башын күтәрде. Сәгыйтьнең кулында бер уч яшел чирәм, ул

аны авызына китерәм дигәндә катып калган, җиргә сыгылып төшкән иде. Асылгәрәй карт, нидер сизенеп, улын кочаклап алды, бала анның кочагына авып төште...

Сәгыйть үлгән иде...

Анның ачык калган зур күзләрендә козгын кошлар шәүләсе чагыла...

Кулында исә бер уч яшел үлән, аны авызына китерәм дигәндә, йөрәге туктап калган иде. Әле унбиш яше дә тулмаган татар баласы кыр-дала уртасында ачтан тәгәрәп үлгән иде...

Ул арада башкалар да йөгереп килеп җитте, Мәһинур абыстай гөрселдәп улы янына ауды. Хәзер аңа ярдәм кирәк иде. Балалар кайсы елый, кайсы әниләре янында, кайсы Сәгыйтьнең мәете кырыенда нишләргә белмичә утыра. Моны күреп, этле сакчылар да атылып килеп җитте, бригадир Коновалов мәетне бер читкә этеп җибәрде дә барысын да яңадан эшкә куа башлады. Әмма Асылгәрәй карт кузгалмады, улының гәүдәсе янында утыра бирде. Моны күреп, башка татарлар да килеп җитте, чөнки бу котырган урысның Асылгәрәй картны кыйнап үтерүе дә бар иде...

— Өлешләрен үзебез эшләп бетерербез, балаларын күмсеннәр, җир өстендә калмасын, — диде алар бригадирга.

Халык, дәррәү кубып, Асылгәрәй картларның өлешен казый башлады, шулай итеп булса да, бу бәхетсез гаиләнең хәлләрен җиңеләйтәселәре килде. Болай да дала тулы мәеттән туйган сакчылар Асылгәрәй картка улын күмәргә рөхсәт иттеләр, чөнки бу мәетләр җир эшкәртергә комачау итә башлаганнар иде.

Баланың гәүдәсен бераз читкә, Урал суы буендагы калкулыкка алып киттеләр. Аягында чак басып торган Мәһинур абыстайны кызлар як-яктан тотты, ә Асылгәрәй карт белән Гыйлемгәрәй Сәгыйтьнең үле гәүдәсен күтәрделәр. Солтанхәким арттан көрәкләр тотып барды. Зәйтуганнан Сабира биреп җибәргән калай чәйнек белән Уралдан су ташып, Сәгыйтьне җиргә яткырып юдылар, чайкап, үз киемнәрен кидерделәр. Аннан караңгыда тау башында кабер казыдылар, Асылгәрәй карт үзе, кыйблага карап, җеназа укыды. Бергәләп казыган тирән чокырга Сәгыйтьнең ябык гәүдәсен салдылар, ул, чытырдатып бер уч яшел чирәм тоткан килеш, мәңгелеккә Урал суы буенда ятып калды...

Дала козгыннары, авыр канатларын шомлы шапылдатып, караңгылыкка кереп югалдылар...

Бала хәзер барысыннан да еракта, мәңгелек тынычлык дөньясында ята иде...

Анның җаны, Урал тауларын бер мизгелдә очып үтеп, барысыннан да алда Зәйтуганга кайтып җиткән, туган нигезе өстендә талпынып йөри иде...

Сәгыйтьнең кинәт үлеме качарга дигән ниятне көчәйтте генә... Бигрәк тә Маһинур абыстай үзгәрде, сәерләнде, инде ачыктан-ачык Зәйтуганга кайтырга җыена башлады. «Балаларымның җаннары барыбер шунда җыелачак, мине дә туфрагым тарта...» — дия иде ул куркыбрак калган Асылгәрәй картка. Ишелеп килгән кайгы-хәсрәттән, чамасыз авыр тормыштан биредә акылга җиңеләючеләр күп иде, шуңа күрә Асылгәрәй карт хатынын да шул хәлгә калмасын дип курыкты. Аннан качу турында бөтен кешегә дә сиздерергә ярамый иде, монда да шымчылар күп, кулакларга беркем ышанмый, бөтенеңне җыеп, төрмәгә илтеп тыгулары да бар. Ә аннан, чыннан да, чыгу юлы юк инде...

Ниһаять, җәй башында тәвәккәлләделәр...

Әсирләр бистәсеннән өч төркемгә бүленеп чыгып китәргә булдылар...

Хатын-кызлар: Маһинур абыстай, Гайшә һәм Мәрзия, кер чайкарга дигән булып, Урал елгасына төшәргә тиеш иделәр. Күпер чыкканнан соң, аргы якта агачлык башлана, ничек тә шунда кереп китәргә һәм беренче авыл тирәсендә башкаларны да көтеп торырга килешенде.

Асылгәрәй карт улы Солтанхәким белән Уралга су керергә төшкән кыяфәт ясарга тиеш иде, юлда көтмәгәндә тотып сорасалар, шулай дип әйтергә уйладылар.

Гыйлемгәрәй исә аларны бистә башында көтеп торып, күпер чыккач бергә очрашырга тиешләр иде. Инде алга таба урман-таулар арасына кереп югалгач, туган якка ни рәвешле кайтасын киңәшерләр, иншаллаһ, хәзергә исә иң мөһиме — бу үлем тегермәненнән котылу, ирекка чыгу иде. Калган барысына да түзәрләр. Кем ничек кайта ала — шулай кайтыр, җәяү икән җәяү, поездга утыра ала икән — поезд белән. Аерым-аерыммы, бергә-бергәме — барыбер атларга, хәрәкәт итәргә кирәк...

Барак халкы, татарлар, яшереп кенә аларга юл өчен тегесен-монысын китерделәр, хәзрәтләр бераз акча да җыеп бирделәр. Һәркем аларның котылып, исән-имин туган якка кайтып җитүен тели иде. Һәм күпләр алар артыннан шушы юлга чыгарга, качарга җыена иде.

Ниһаять, Асылгәрәй хәзрәтнең алты җанга калган гаиләсе тәвәккәлләп озын юлга кузгалды.

Сөйләшенгәнчә, Урал суы буена өч яктан төштеләр.

Әсирләр шәһәрчегенең, җир асты куышларының игечиге күренми иде.

Бөтен җирдә кара төтен, төзелеш кайный, җирләр актарыла, завод торбалары улый, машиналар кычкырта, атлар кешни, кешеләр сүгенә.

Тачкалар тотып, коллар чатыр чаба, алар, бөкрәеп килеп, һаман кирпеч ташыйлар, корт кебек һаман җир казыйлар, һаман стена өяләр, бетон салалар.

Үлеп бетмәгән чабаталы татарлар Магнитка төзи.

Илгә танклар кирәк, тракторлар кирәк, тимер гиганты кирәк.

Кеше генә кирәк түгел...

Аларны каннарын сыкканчы эшләтәләр дә ач далага чыгарып ташлыйлар.

Аларны анда мәет козгыннары көтеп тора. Чөнки бу илнең, бу хакимиятнең, бу кавемнең тәртибе шундый.

Ул үзе дә кеше кебек яши белми, башкаларга да ирек бирми. Ә Асылгәрәй хәзрәтнең затлы нәселе, үзләре өчен әзерләнгән тимер казаннарда кайнап, чуен кешеләргә әйләнергә уйламый. Аларның үз җирләрендә татар булып, мөселман булып, кеше булып каласылары килә...

Шуңа күрә алар бу кара тормыштан качып баралар. Инде бер еллык газап артта калып бара, алда — кырык сырты белән кыйтгаларга таралып яткан Урал таулары, татар иле, татар дөньясы көтеп тора.

Алда — туган як, Шөгер урманнары, Зәй сулары, туган авыл, туган нигез.

Алда — ирек, әсирлектән азат булу, бәйсез тормыш...

* * *

Чиләк төбенә юеш керләр салып, Мәһинур абыстай кызлары белән башта Урал елгасына таба китте.

Бу — ял көн, июнь башы иде. Урал елгасы да сөрген зонасына кергәнгә һәм бирегә хатын-кызларның кер чайкарга йөрүләре гадәти хәл булганга, бистә читендә торучы мылтыклы сакчылар аларны шикләнүсез уздырып җибәрделәр. Мәһинур абыстайның йөрәге дөп-дөп итеп типте, чиләк тоткан кулы берни тоймый башлады. Гайшәбикә белән Мәрзия исә куркып һәм кызыксынып як-якларына караналар. Алар өсләренә бар булганнарын кат-кат кигәннәр, аякларында яңа чабаталар, шулар белән туган якларына кайтып җитәргә хыялланалар иде...

Инде әсирләр бистәсе дә шактый читтә калып бара, мылтыклы сакчылар да күренми башлады, ә алар яр читләтеп һаман баралар да баралар. Гел артларыннан кемдер йөгереп килеп туктатыр кебек. Әмма, ни гаҗәп, арттан беркем дә килми, аларны эзләүче дә, куучы да күренми. Хәер, биредә алар кебек бәрелеп-сугылып йөрүчеләр күренгәли, чөнки моннан ары барыбер беркая китеп булмаслыгын барысы да белә...

Менә качкыннар, батыраеп китеп, Песчаный күперенә дә

якынлаштылар, менә инде юл буйлап тасма кебек сузылган куаклыкка да кереп киләләр. Ә аның артында инде урман, тимер юлга хәтле аннан да барырга була. Асылгәрәй хәзрәт белән бу тирәдәге беренче татар авылы янында очрашырга килештеләр, ә Гыйлемгәрәй аларны күпер янында ук куып җитәргә тиеш иде...

Шулчак арттан йөгергән, кычкырган авазлар ишетелде. Буылып-буылып этләр өрде, кемдер шартлатып атып җибәрде, тагы, тагы атты.

Маһинур абыстайның аяклары тотмас булды. Гайшәбикә, аны һәм Мәрзияне өстерәп диярлек, урман эченә йөгерде. Бәреләсугыла шулай бераз баргач, калкулык кебек җиргә менеп җиттеләр һәм ачыклыктан аска карадылар. Ә анда, кулларын бу якка таба сузып, Гыйлемгәрәй йөгерә иде. Менә ул атылып күпергә килеп керде, тагы бер-ике сикерсә, ул урман эчендә, әнисе һәм туганнары янында булачак. Шушыны сизгәндәй, аның артыннан гөрселдәтеп атып җибәрделәр. Гыйлемгәрәй йөгерүен белде. Аннан соң ананың күз алдында бар дөнья буталды, улының артыннан үлем куып килә иде...

Менә аның улына төбәп тагы, тагы аталар. Гыйлемгәрәй йөгереп барган уңайга сөрлегеп туктап кала, гаҗәпләнгәндәй артына борылып карый. Шулчак тагы гөрселдәтеп атып җибәрәләр. Гыйлемгәрәй очып китә алмыйча интеккән яралы кош кебек талпынып тора да Урал суына барып төшә. Елга өстендә аның «Әни!» дип кычкырган җан авазы гына эленеп кала...

Уралның болганчык суы аны бик тиз үзенә бөтереп ала, бәргәли-бәргәли түбәнгә агызып алып төшеп китә. Казах-Ырынбур далалары буйлап, Хәзәр диңгезенә хәтле бик озак тибрәтеп алып барыр әле ул Гыйлемгәрәйнең үле гәүдәсен. Ә бәлки, анда да алып барып җиткермәс, елганың бер борылышында яр буена чыгарып атар. Бәлки, ул шушы тирәдә үк мәңгегә су төбендә ятып калыр. Шулай итеп, Асылгәрәй карт белән Маһинур абыстайның унҗиде яшьлек галим уллары Гыйлемгәрәй бу вәхши илнең мәңгелек төрмәләреннән котылыр.

Боларның барысын да үз күзләре белән күреп торган ана, агач араларыннан чыгып, су буена йөгерергә омтыла, әмма кызы Гайшәбикә аны чытырдатып тоткан, бер җиргә дә җибәрми. Чөнки ул күреп тора, әнә Гыйлемгәрәй артыннан ук күпергә мылтыклы сакчылар йөгерешеп керделәр, алар шатыр-шотыр әле су өстенә, әле тирә-якка аталар, юлларына кем чыкса да, атып үтерәчәкләр. Шуңа күрә, инде ни генә булса да, алар янына чыкмаска, күренмәскә кирәк. Күренсәләр, аларның үзләрен дә шушы ук хәл көтә. Тотсалар, күрсәләр, йә — үлем, йә — төрмә, башка юл юк.

Мәһинур абыстай үзе дә моны яхшы аңлый, әмма күзләрен яшь каплый, зиһенен бала хәсрәте томалый. Улы артыннан Урал суына сикермәс өчен, ана тырнакларын кара җиргә батыра, агач тамырларына чытырдатып ябыша. Һәм йөзен җиргә каплап, үксеп елый, яралы җанвар кебек ыңгырашып үкерә. Колак төбендә улының «Әни!» дип кычкырган соңгы сүзе яңгырап тора. Үзәк өзгеч ул аваз атылып Урал тауларына килеп бәрелә, кырык сырт аша очып үтеп, туган якларны урап кайта, аннан, исәр җил булып, тагы ананың аяк астына егыла.

«Әни... Әни... Әни...»

Ул арада кораллы сакчыларның, күперне чыгып, бу якка таба килгәннәре күренде. Алар, нәрсәгәдер шикләнеп, мылтыкларын төбәп, урманга таба атлыйлар иде. Чөнки, гадәттә, качучылар ялгыз гына булмый, алар, урманда очрашып, алга таба бергәләп юлларын дәвам итәләр. Бу юлы да шулай булырга мөмкин. Шуңа күрә сакчылар, урман ягына төбәп, шатырдатып атып җибәрделәр. Бурзай этләре, бу якка карап, буыла-буыла өрергә тотынды. Әле ярый Мәһинур абыстай кызлары белән бергә җиргә капланып яткан иде, аткан пулялары чытырдап баш очыннан гына сызгырып үттеләр. Ана бу балалары өчен дә үлем әзерләнгәнен, аның үз артларыннан эзәрлекләп килүен сизде. Балаларын күрәләтә харап итәргә ананың хакы юк иде. Һәм ату тавышлары бераз тынуга, ул, кызларын җитәкләп, куе урман эченә таба йөгерде. Җәйге урман аларны үз кочагына суырып алды.

Озак, бик озак йөгерде алар куе агачлар арасыннан. Әле юан-юан тамырларга, мүк баскан ташларга абынып егылдылар, әле җәтмә кебек куаклыкларга чорналдылар, әле, үрмәләп диярлек, тагы торып йөгерделәр. Алар кай тарафка йөгергәннәрен дә, кая барганнарын да белмәделәр, аларга бары тик бу каһәр төшкән урыннан ераграк качарга, ераграк китәргә кирәк иде. Инде ату тавышлары да бик еракта калды, этләр өргәне дә тонык ишетелә башлады, урман эче дә куерганнан-куера, караңгыланганнан-караңгылана барды. Ә алар атладылар да атладылар. Асылгәрәй карт нindидер авыл турында әйткән иде, ул авыл да күренмәде, олы юл да, кешеләр дә барысы да еракта, бер читтә калды.

Мәһинур абыстайның эченә шом керә башлады — карты белән кайда очрашырлар соң алар? Нинди авыл турында әйтте икән ул? Бу кара урман эчендә бернинди авыл да, кешеләр дә күренми бит. Әллә адашулары, бер-берсен югалтышулары шушы буламы? Алар башта ук, очраша алмасак, кем ничек кайта ала, шулай кайта, дип сөйләшкәннәр иде. Әмма ул вакытта хатын-кызлар янында Гыйлемгәрәй булса да булыр дип уйланылган иде. Менә хәзер аларның яннарында

сакларлык, якларлык бер ир-атлары да юк. Ә урман тулы ерткыч җәнлек, ерткыч җанвардан да куркынычрак кешеләр. Үзен дә, кызларын да харап итеп ташламасlinks?

Маһинур абыстай атлаган саен Алладан ярдәм сорады...

Аның кара урман кебек бу тормышында Аллаһтан башка бер ярдәмчесе дә юк иде.

Алар көне буе шулай бардылар да бардылар.

Юлда чишмәләр очратып, берничә тапкыр каткан ипиләрен шунда җебетеп ашадылар, аланлыклардан әнис, какы кебек үләннәрне җыеп каптылар. Әкренләп аларга тормыш дәрте, караңгылыкта югалган рух, өмет кайта башлады. Чөнки монда бөтенләй башка дөнья иде. Җырлап, чыңлап, зеңгелдәп торган саф, кыргый, якты дөнья иде. Ун ай әсирлек газапларыннан соң, салкын, пычрак бараклардан соң, авыр эштән соң бу дөнья аларга җәннәт булып күренде. Әгәр Гыйлемгәрәй хәсрәте дә булмаса, алар шушы саф дөньяда бер көн яшәп кала алуларына да чиксез рәхмәтле булырлар иде. Бу дөньяда алардан бәхетле кеше булмас иде.

Ә табигать дөньясы, чынлап та, әкияттәге кебек могҗизага тиң.

Аңа бөек төзелешләрең ни дә, бөек идеяләрең ни...

Ул барыбер үзенчә, үз кануннары белән яшәп ята.

Аяк астында мең төрле бөҗәге мәш килә, баш очында мең төрле кошлары сайрап тора. Ул һаваның сафлыгы — башлар әйләнеп китә, ул чишмә суларының шифасы — эчкән саен көч бирә. Боларны күреп, кечкенә Мәрзия бигрәк тә нишләргә белми, әле, колын кебек, хәтфәдәй җиргә ятып ауный, әле, балыктай, чишмә суларында чупырдый. Бала күзгә карап үзгәрде: йөзенә шатлык чыкты, күзләрендә гаҗәпләнү, соклану барлыкка килде. Аның бер мизгеллек шушы бәхете, ирегe өчен генә булса да ул җәһәннәм базыннан качу кирәк иде.

Ә таулар!..

Аларның мондый биек тауларны әле беркайчан да күргәннәре юк иде...

Ул тауларның кайберләре кап-кара граниттан, кайберләре ап-ак мәрмәрдән икән, кояш нурларында алар елкылдап, ялтырап торалар. Әкияттәге көзгеләр патшалыгы сыман. Аларда каршыдагы тауларның кара урманнары чагыла, зәңгәр күк йөзе тибрәлә. Кайбер таулар гел шулай тоташ ташкыялардан тора, кайберләрен исә яшел урманнар каплаган. Тау араларыннан челтерәп чишмәләр агып чыга, алар, кыяташлардан түбән сикереп, шарлавык ясыйлар. Шарлавыклар исә тау елгаларына коялар.

Каядыр, бик ерак та түгел, поезд кычкырткан тавышлар ишетелә, димәк, бу тирәдән тимер юл да ерак түгел. Бу та-

выш качкыннарны тагы кырыс дөньяга кайтара, үз кайгыларын исләренә төшерә. Әйе, аларга, Асылгәрәй хәзрәт әйткәнчә, урман эчләтеп аска төшеп, поезд юлына якынаерга кирәк. Бу тау араларыннан хатын-кыз озак бара алмас, барыбер кешеләр янына чыгарга кирәк булыр. Хәзергә алар бары тик чама белән генә баралар, әмма тау араларына үк кереп китмәделәр. Зур дөнья тимер юл тавышлары, паровоз кычкыртулары белән үзенең барлыгын искәртеп тора.

Ул арада Урал тауларына төн килде.

Әле җәй башы гына булганлыктан, артык җылынып та өлгермәгән җирдән салкын бәреп тора башлады. Бу якта төннәр, гомумән, салкынчарак була, моны Маһинур абыстайлар яхшы белә иде инде. Шуңа күрә өсләренә алдан ук бар булганнарын киенеп чыкканнар иде, анысы бик тә ярап куйды. Балалар да шактый арыганнар иде, каядыр төн чыгарга да кирәк, шуңа күрә бер тау куышында туктарга булдылар. Эчтә коры һәм тыныч иде, әйтерсең лә юлаучылар өчен махсус уелган таш мәгарә. Якты күздә урам ягыннан чыршы, карагай ботакларын җыеп алып керделәр, аны аска түшәделәр, баш очына салдылар. Өсләренә абыстайның олы бер шәлен капладылар, ябынырга тагы бер шәл калды. Йоклар алдыннан якындагы чишмәдә тәһарәт алдылар, тау куышында иркенләп, беркемнән курыкмыйча, тынычлап намаз укыдылар. Аннан куыш авызына зур таш терәп, кечкенә Мәрзияне уртага алып, соңгы ун айда беренче тапкыр кешечә йокларга яттылар.

Качкынлыктагы бер көннәре аларга күп нәрсәләр күрсәтеп өлгергән иде инде — Гыйлемгәрәй хәсрәтен дә, ирек бәхетен дә.

Алда тагы ниләр буласын бары тик бер Алла гына белә иде...

Төн бик тыныч үтте. Иртән аларны кошларның өздереп сайравы уятты. Бертын, кузгала алмыйча, кайдалыкларын аңышмыйча яттылар.

Ылыс исе белән тулган тау куышы, өстә урман шаулавы, аяк очында чишмә челтерәве, кошлар сайравы. Кичә генә алар таңны сасы, караңгы баракта каршылаганнар иде, бүген иректә, табигать кочагында яталар. Юк, бу төш түгел, алар, чыннан да, иректә, Магнитка әсирлегеннән качып котылганнар иде.

Инде барысы да кичәге көндә калды...

Тоткын тормышы да, качу да, Гыйлемгәрәй дә...

Кайдадыр, шушы урман эчендә, Асылгәрәй карт белән Солтанхәким йөрергә тиешләр, насыйп булса, алар белән дә күрешерләр. Иң мөһиме — алар хәзер барысы да иректә, алар

хәзергә барысы да исән. Гыйлемгәрәй генә бу якка чыга алмады, ике арадагы таш күпердә өзелеп калды. Инде калган балаларны исән-имин саклап, илгә кайтып җитәргә кирәк... Шулай җайлы гына кача алулары һәм беренче төннең тыныч узуы Маһинур абыстайның күңеленә өмет салды, ул хәзер туган якларга кайтып җитәселәренә шикләнми иде...

Якында гына челтерәп аккан чишмә суында бит-кулларын юдылар, тәһарәтләнеп, иртәнге намазларын укыдылар. Киптергән ипи әле шактый иде, аны, чишмә суына манчып, ашап куйдылар. Мәрзия ул арада җиләк яфраклары, әнис, какы кебек үләннәр җыеп килде, аларны да рәхәтләнеп ашадылар. Җирдән хәтта узган елгы чикләвекләргә хәтле табып ашадылар. Бу алар өчен кунак сыеннан да артык иде. Бигрәк тә Мәрзия рәхәтләнде, әле, йөгереп барып, каен суына авызын куйды, әле, җыеп алып, нарат сагызы чәйни башлады. Урманда табылган һәрнәрсә аңа могҗиза булып, дөньядагы иң тәмле ризык булып тоелды. Яңадан таш төрмәләренә кайтмас өчен, бала гомер буе шушы урманнарда үлән ашап яшәргә дә риза иде.

Инде яңадан юлга кузгалырга да була иде...

Поезд тавышы сул яктан килә, димәк, шунда таба юл тотарга кирәк. Инде Магнитка шактый еракта калды кебек, бәлки, бу тирәдән эзләп тә йөрмәсләр, шәт. Башкалар шулай кача бит, кире кайтмаганнары, тотылмаганнары да бар... Ни булса да, язылганы булыр инде, анда тереләй үлем көтеп яту булмас...

Шулай ярты көн чамасы баргач, поезд тавышы тагы да якынрак ишетелә башлады. Аның юлы каядыр шушы тирәдән генә үтә иде. Чираттагы тауны үрмәләп диярлек менгәч, алар каршыда дегетләнеп беткән тимер юл күрделәр. Әмма бу тирәдә генә бернинди станция-мазар күренми, анысын әле эзләп табарга кирәк иде. Шушы тимер юл буенчарак барсаң, барыбер берәр станциягә килеп чыгарга мөмкин иде.

Качаклар да шулай итәргә булдылар...

Алар олы юлга ук чыгарга курыктылар, юлны чамалап, куаклар арасыннан гына киттеләр. Болай бару, әлбәттә, җайсызрак иде, әмма барыбер билгесезлек түгел. Алда юл бар, димәк, ул барыбер каядыр килеп чыгачак. Бәлки әле Асылгәрәй хәзрәт тә шунда турылап чыгар, ул ир-ат кеше, алар кебек урап, адашып йөрмәс. Насыйп итсә, шунда очрашып, киңәшерләр, мөмкин булса, поездга да утырырлар. Ул хәтле кеше арасыннан гел документ тикшереп йөрмәсләр әле, ә юлга акчалары бар аларның, шөкер...

Шундый уйлар белән дәртләнеп, туктап ял итә-итә, кичкә таба тимер юл станциясенә дә килеп җиттеләр. Монда халыкның чиге-чамасы юк иде, әйтерсең лә бөтенесе кубары-

лып юлга чыккан. Арада кораллы сакчылар да күренә, алар халык арасында йөреп, тикшереп торалар. Качакларның иң курыкканы әнә шул кораллы сакчылар иде. Чөнки аларның берсендә дә документ кисәге юк. Димәк, ничек тә аларның күзләренә чалынмаска, шик уятмаска кирәк. Ничек тә кеше арасына кереп югалырга һәм тизрәк поездга утырырга...

Башта, куак арасыннан чыкмыйча гына, станциядәге халыкны күзәттеләр. Монда һәркем үз эше белән мәшгуль иде, беркемнең беркемдә кайгысы юк кебек. Кемдер нидер сата, кемдер ала, кемдер поезд көтә. Арада болар кебек шактый фәкыйрь кешеләр дә күренә, яхшы киенгән адәмнәр дә бар. Кораллы сакчылар халык арасында бер күренеп китәләр, бер бөтенләй юкка чыгалар. Аларның китеп торган вакытларын чамалап, урманнан чыгарга, халык арасына кереп югалырга кирәк иде...

Шулай иттеләр дә...

Шик уятмас өчен, берәм-берәм чыгарга, сатучы хатын янына җыелырга булдылар. Башта Гайшә чыкты, чөнки кечкенә Мәрзиянең берүзен анда чыгарырга да, монда калдырырга да ярамый иде. Гайшә, берни булмагандай, төенчеген тотып, сатучы хатын янына килеп басты. Ул шактый торса да, аның янына килүче, тикшерүче күренмәде. Аннан урман эченнән йөгереп Мәрзия чыгып китте, ул туп-туры апасы янына килеп басты. Алар берни булмагандай сөйләшә башладылар, үзләре сиздерми генә тирә-юньне күзәттеләр. Яннарына килүче, кызыксынучы булмады. Моны күреп, Маһинур абыстай да качкан җиреннән чыгып, балаларына килеп кушылды. Хәзер, вакытны сузмыйча, поездга утыру, тизрәк моннан китү ягын кайгыртырга кирәк иде...

Балаларын сатучы хатын янындагы буш эскәмиягә утыртты да, Маһинур абыстай вокзал ягына билет белешергә китте. Бергәләп йөрсәң, шикләнерләр, тотып тикшерә башларлар дип тә курыкты ул. Тиздән Уфа ягына поезд була, дип әйттеләр, әмма кассада кеше өстендә кеше иде. Кемнәр генә юк иде монда: бер көтү бала иярткән чегәннәр дә, хәерче сукбайлар да, эшчеләр дә, чабаталы авыл халкы да. Барысына да Уфа ягына китәргә кирәк булып чыкты, зур дөньяга юл бары тик шуннан гына иде.

Маһинур абыстай, билетка чират алганнан соң, кызлары белән киңәшеп алды. Бу хәтле халыкка билет җитү икеле иде. Шуңа күрә, ничек булса да, билетсыз утырырга тырышырга кирәк. Чөнки алар монда төнгә кала алмыйлар, тотып тикшерүләре бар. Поезд килеп туктау белән, кайсы вагонга керә алсалар, шунда утырырга килештеләр, аннан юлда яки Уфада очрашырга булдылар. Алай да аймыл булалар икән, кайсы яктан булса да, Бөгелмәгә хәтле кайтырга

килештеләр. Аннан инде Зәйтуган кул сузымында гына кала...

Шулай килешеп, Маһинур абыстай вокзалга билет чиратына кереп китте. Чират бер дә урыныннан кузгалмаган, бер кечкенә генә тәрәзәгә дөнья хәтле кеше өелгән, барысы да билетсыз, барысына да Уфа ягына кирәк иде. Ул арада кемдер поезд килә, дип кычкырып җибәрде, ярты халык аның артыннан урамга ташланды, яртысы билетка басып калды. Чират бераз урыныннан кузгалган кебек булды, кешеләр кулларына билет тотып чыга башладылар. Маһинур абыстайның чираты да инде якынайганнан-якыная бара иде, чөнки күп кеше билетсыз утырырга чыгып йөгергән иде. Маһинур абыстай билет белән барыбер ышанычлырак булыр дип уйлады, һәм поезд инде китәргә торганда, кулына билет тотып, урамга йөгереп чыкты. Әмма вокзал мәйданында кызлары да, пирожки сатучы марҗа хатыны да юк иде...

Моны күреп, башта ана кеше шашып калды, әле бер кешегә, әле икенчесенә килеп, кызлары турында сорады. Әмма беркем берни белми, барысында да поездга әләгү кайгысы иде. Ананың башыннан меңтөрле уй үтеп китте, өмет белән китәргә торган поезд янына йөгереп килде. Ул бит кызларына үзе үк җай чыкса, утырырга тырышыгыз, юлда табышырбыз, дигән иде, димәк, алар инде поездда булырга да мөмкин. Әмма монда бер генә ишеккә, бер генә тәрәзәгә дә якын килә торган түгел, бөтен җирне кеше сарган, кайда — аяк, кайда баш икәнлеген дә белерлек түгел.

Поезд тагы бер тапкыр ачы итеп кычкыртып җибәрде...

Вокзал бинасы ягыннан мылтыклы сакчылар килеп чыктылар һәм бу якка таба килә башладылар. Алар ишек-тәрәзәләргә асылынган кешеләрне йолкып-йолкып аталар, үзләре белән җыеп, вокзал бинасына алып китәләр иде. Моны күреп, Маһинур абыстайның коты чыкты, ул, билетсыз кешеләрне ыра-ера, ишеккә атылды. Кулындагы билетын күргәч, тикшерүче хатын аны тиз генә эчкә кертеп җибәрде дә биек баскычларны шартлатып тартып алды. Тар коридорда кысылып торган халык төркеме Маһинур абыстайны эткәләп-төрткәләп эчкә алып кереп китте. Ул арада поезд соңгы тапкыр ачы итеп кычкыртып җибәрде, ишекләр ябылды, состав көзән җыергандай тартышып куйды һәм алга ыргылды. Билгесез станция төн караңгылыгына кереп югалды, Маһинур абыстай Уфа ягына утырып китте...

Ул кызларын юлда яки Уфада эзләп табасына чын күңеленнән ышана иде, шул ук вакытта күңелендә нindидер шом да бар. Юлга чыкмас борын таралдылар да беттеләр. Асылгәрәй хәзрәт тә бер җирдә дә юк, кызлар да көтмәгәндә юкка чыкты. Инде, Раббым, ахыры хәерле булсын, туган якларга

исән-имин кайтып җитәргә насыйп итсен. Зәйтуганга кайтып җитә алса, үлсә дә үкенмәс иде ул. Мәһинур абыстай үзе дә аңламаган ниндидер тойгы, көч аны котылгысыз рәвештә Зәйтуган ягына өстери, төрмәләрне, тауларны җиңеп, туган җиргә кайтырга өнди иде. Аны туган туфрак тарта, әмма мәңгегә үз куенына алыр өчен тарта. Мәһинур абыстай моны сизенә, шуңа омтыла, чөнки аның бөтен курыкканы Магнит далаларында ятып калу иде.

Менә хәзер ул алардан мәңгегә китеп бара...

Үз җирендә туфрак булыр өчен, Урал тауларындагы кырык сыртны кичеп, Зәйтуганга кайтып бара.

Ә бу вакытта аның кызлары кораллы сак астында яңадан Магниткага кайтып баралар иде.

* * *

Мылтык аскан ул урыс кешесе әллә каян гына — вокзал бинасы артыннан килеп чыкты да туп-туры Гайшә белән Мәрзия янына килеп басты. Ул аларның өс-башларына бер генә күз төшереп алды һәм барысын да аңлады. Инде тетелә башлаган кат-кат киемнәре, җәелеп киткән чабаталары аларның качаклар икәнлеген кычкырып тора иде. Болар кебек төзелештән качучылар хәзер биредә дистәләгән, йөзләгән, шуңа күрә һәр станциягә өстәмә каравыл куелган. Бу тирәдәге авылларны да һәр атнада бер әйләнеп, тентеп-тикшереп торырга туры килә, чөнки шунда качып ятучылар да бар. Поездларда да тикшерү көчле, шулай итеп, качучыларның бер өлешен тотып кире Магниткага озаталар. Качакларның бер өлеше исә юлда ук үлеп кала, чөнки Урал тауларына ике башлы кеше генә керергә батырчылык итә...

Сакчы тәртип өчен аларның документларын сораган булды. Гайшә, Магниткада өйрәнгән бераз урысчасы белән, үзенчә хәлне аңлатырга тырышты. Имеш, алар шушы тирәдәге татар авылыннан икән, имеш, хәзер Уфага баралар. Әмма сакчы алардан документ таләп итте, ә аларның берниләре дә юк иде. Кораллы сакчы кызларга үзе белән барырга боерды. Моны ишетеп, Мәрзия: «Әни кала, әни», — дип елый башлады, бармаска аякларын терәде. Гайшә исә барысын да аңлаган иде инде — аларны тоттылар. Аларны хәзер яңадан Магниткага сөрәчәкләр. Аның күңеленнән: «Ичмасам, әни булса да котылсын бу төрмәдән, китсен моннан», — дигән уй чагылып үтте. Ул сакчыга вокзал бинасында әнисе калганын әйтмәде. Апасының тыныч барганлыгын күреп, Мәрзия дә елавыннан туктады.

Сакчы аларны тимер юл буйлап бөтенләй кире якка алып китте.

Бераз баргач, алар бер тыкрыкка борылдылар. Анда, юлның як-ягына тезелеп, бик күп кеше утырган иде, аларны бөтен яктан кораллы сакчылар чорнап алган. Гайшәләрне дә шулар янына китереп туктаттылар. Халык күп, бер йөзләп кеше булыр. Гайшә алар арасында Магниткага сөрелгән татарларны да күреп алды. Әйе, алар да качып барган вакытта тотылганнар һәм яңадан шунда сөреләләр иде.

Бераз шулай җыя төшкәч, аларны көчле сак астында урман буйлап алып киттеләр. Инде тәмам караңгы төште, кечкенә балалар арып елаша башладылар. Барысы да ач иде, җитмәсә, төнге салкын өшетә, калтырата да башлады. Ә алар һаман баралар да баралар. Мәрзия атлаган саен абына, сөртенә, ул, көне буе урманда качып йөреп, бик нык арыган, инде аягүрә йоклый иде. Гайшә аның кулыннан чытырдатып тотты, чөнки егылып калса, аны беркем күтәрмәячәк, алдырмаячак иде...

Караңгыда аларны бер авылга куып керттеләр...

Анда ике буш бура тора иде, тоткыннарны икегә бүлеп, шунда яптылар. Эт булып арыган халык шунда ук гөрселдәп җиргә ауды, кешеләргә инде ашарга да, эчәргә дә кирәкми, бары тик йокы, ял гына кирәк иде. Шушы мизгелдә Гайшә үзенең әнисе урынында калганлыгын аңлады. Алар белән ни генә булса да, сеңлесе Мәрзиянең язмышы өчен хәзер ул җавап бирә иде. Ул сеңлесен куенына алды, коры җиргә яткырып, салкын тидерәсе килмәде. Өстенә төенчектә калган чүпрәк-чапракларны өйде. Мәрзия, ана куенындагы сабый кебек, апасын кочаклап йокыга китте. Бу аларның ирektә соңгы төннәре иде. Әгәр моны ирек дип әйтергә яраса...

Иртә белән буралар янына бер атлы арба килеп туктады. Кечкенә балаларны шунда утырттылар. Гайшә сеңлесе Мәрзияне дә тизрәк шулар янына төртте, кулына калган сохарилар белән төенчеген тоттырды. Калган бөтен халыкны — картын-яшен, ир-атын, хатын-кызын — дүртәр итеп сафка тезеп, арбага тагып, Магнитка ягына алып киттеләр. Аларны алдан-арттан, уңнан-сулдан атка атланган мылтыклы конвой озата бара иде. Ач, хәлсез, авыру кешеләр көне буе җәяү атладылар, егылганнар шунда әҗәл көтеп ятып калдылар. Аларның инде туган җиргә качарлык та, яңадан сөргенгә кайтырлык та хәлләре юк иде. Гайшә тагы бер кат әнисенең станциядә калуына, бу мәхшәрне күрмәвенә сөенде. Әнисе моңа түзә алмас иде, соңгы вакытта ул бик бетеренде, Гыйлемгәрәйнең үлеме исә аны бөтенләй бетерде. Аның инде үлгән балалары артыннан чыкмаган җаны гына калды. Зәйтуганга кайтып җитә алса, бәлки, терелеп китәр, яңадан яши башлар...

Ул арада коеп яңгыр яварга тотынды.

Ач, хәлсез, пычранып беткән кешеләр, битләрен яңгыр астына куеп, бераз хәл алган кебек булдылар, аны тамчылап йоттылар. Әмма аяк атлау тагы да кыенлашты, күпләр таеп егыла башладылар, аларны кыйнап тагы торгыздылар, тагы кудылар. Кичкә таба Магнитка да күренә башлады, ул меңәрләгән бараклары, землянкалары, завод торбалары, домна мичләре, актарылып ташланган төзелеш мәйданнары белән дәһшәт чәчеп ята иде. Әйтерсең зур бер төрмә. Аның бөтен тирә-ягы чәнечкеле тимерчыбык белән уратып алынган. Хәзер инде аны тагы да ныграк саклый башларлар, чөнки качучыларның иге-чиге юк, ә эшләргә кеше кирәк. Һәм качкан колларны, тотып алып, арба артына бәйләп, яңадан төрмәләренә алып кайталар иде...

Вакыйга 1932 елның җәендә, СССР империясендә бара иде...

Төнгә каршы качкан әсирләрне үзләре элек яшәгән Иске Северный тоткыннар бистәсенең комендатурасына китереп ташладылар. Комендатураның үзендә үк тәртип бозучылар өчен тәрәзәләре рәшәткәле берничә бүлмә бар иде, әсирләрне шунда кертеп тутырдылар. Комендант Шишкалов, инде кара төн булса да, монда иде, ул качаклар өстенә, йодрыкларын төйнәп, котырган эт кебек ташланды:

— Сгною в тюрьме, татарская морда! — дип, ул әле бер татарның, әле икенчесенең бугазына килеп ябышты, хәлсез әсирләрне кирза итекле аяклары белән типкәләде.

Шишкалов Гайшәнең дә эченә тибеп җибәрде, кыз сыгылып төште, тик дәшмәде. Ул бөтен көченә сеңлесе Мәрзияне сакларга, аны кыйнатмаска тырышты. Бу кыен-җәберләрнең әле башы гына икәнлеген ул инде сизенә иде, чөнки тотылган качакларны Магнитканың иң куркыныч төрмәсе көтә. Ул төрмә турында җан өшеткеч нәрсәләр сөйлиләр, анда кергән кеше инде исән чыкмый иде...

Гайшә сеңлесе белән бергәләп соңгы төн уздырганын сизде, аңа иң кирәк нәрсәләрне әйтеп калдырырга тырышты. Мәрзия әле кечкенә, аны төрмәгә утыртмаслар, ә Гайшәне, таң атуга, туп-туры шунда алып китәчәкләр. Ул аннан кайчан чыгарын белми. Шуңа күрә сеңлесе өчен бик борчыла, аңа үзенең киңәшләрен биреп калдырырга тырыша...

— Син үзебез яшәгән баракка кайт, сеңлем, — диде ул, аны кочагыннан ычкындырмыйча. — Анда белгән кешеләр бар, шулар янына сыен. Ни булса да, үзебезнең татарлар янына бар, мөселманнарга сыен. Артыгын сөйләмә, әни турында да берни әйтмә, урманда ук адаштык, диген. Алла язса, мин кайтырмын, сеңлем, сабыр итеп, бер-беребезгә догада булыйк...

Мәрзия аның бөтен сүзләрен аңлап та бетермәде.

Иң мөһиме — ул бүген апасы белән бергә иде, ә иртәгә нәрсә була — бала анысын күз алдына китерә алмады...

Апасының әкрен генә сөйләгән тавышына ул эреп йокыга китте.

Ул төшендә тагы Зәйтуганны, бакча башыннан гына агып яткан зур елганы, анда йөзеп йөргән игезәк туганы Рәйсәне күрде. Рәйсә әле балыкка әйләнеп, елганың төбенә үк төшеп китә, әле кош булып, Зәйтуган өстендә очып йөри башлый. Һәм үзе артыннан Мәрзияне дә чакыра. Әмма Мәрзия аның кебек оча да алмый, балык булып суда да яши алмый икән. Шуңа күрә алар берничек тә кавыша алмыйлар икән. Моны аңлап, Мәрзия елый-елый Зәйтуган буйлап йөгерә, аның тизрәк мәчеткә кереп әтисен алып чыгасы, Рәйсә турында сөйлисе килә. Ә әтисе мәчеттә юк, анда җеннәр туй итә. Алар барысы да Магниткадагы мылтыклы сакчыларга охшаган. Менә алар Мәрзияне этә-төртә мәчеттән куалар, беләгеннән тотып селкиләр. Авыртуга чыдый алмыйча, Мәрзия күзләрен ача һәм башта берни аңламыйча тора. Аны кичәге сакчылар төрткәли икән, аларның барысын да кыйнап урамга куып чыгардылар. Аннан исә, сафка тезеп, Магнитка буйлап алып киттеләр.

Аларны шул рәвешле шәһәр мунчасына куалар иде. Имеш, качакларны беттән һәм тифтан арындыралар, үзләренчә тәртиптә тоталар. Мунчаның ирләр һәм хатын-кызлар өчен билгеләнгән көннәре бар, әмма качакларны, җәза йөзеннән, барысын бергә кертәләр. Мөселман хатын-кызлары өчен, ак сакаллы татар картлары өчен моннан да зур җәза була алмый, әлбәттә. Менә бүген дә аларны, ир-атын һәм хатын-кызын, урысын һәм татарын, яшьләрне һәм картларны — барысын бергә салкын мунчага куып керттеләр. Сәләмәләренә чытырдап ябышкан татар хатын-кызларының өсләреннән киемнәрен сыдырып тартып төшерделәр, чәч-башларына агулы су сиптерә башладылар. Су сасы һәм хлорлы иде, ул әле боз кебек салкын була, әле бөтен тәнне пешерә башлый. Халык хайван тавышлары чыгарып акыра, кемдер елый, кемдер сүгенә, каргана. Татар бабайлары, шәрәлек оятыннан, битләрен каплап идәнгә чүгәләр, аларны тартып торгызып, өсләренә аяктан егылганчы сасы су сиптерәләр. Бабайлар шул идәндә ятып кала...

Мәрзия, куркуыннан һәм оятыннан чырыйлап, апасы артына качты, апасы исә үзе кая барырга белми иде...

— Сеңлем, чүгәлә, чүгәлә, башыңны тотып утыр, күзләреңне сакла! — диде ул, сасы суга тончыга-тончыга.

Алар, кочаклашып, тизрәк идәнгә чүктеләр, бу хурлыктан һәм агулы судан шулай качып калырга тырыштылар. Башка татар хатын-кызлары да, битләрен каплап, идәнгә чүктеләр, әмма комендант Шишкалов үзе, мунчага кереп, аларны өстерәп торгызып йөри иде.

— Мы вам кино покажем, татарва! Мы вам покажем, как бежать! — дип кешни-кешни, ул татар кызлары өстенә боздай су сиптереп йөри иде.

Мунчадан соң аларны төркемнәргә бүлделәр.

Бала-чаганы яңадан баракларына кайтарып җибәрделәр, калган бөтен халыкны Магнитка төрмәсенә җыеп алып киттеләр. Хәтта үләргә торган карт-карчыкларны да җәлләп тормадылар, властьлар өчен алар барысы да качаклар иде. Әлбәттә, бу татар картлары анда үләргә баралар иде...

Менә алар, куллары бәйле хәлдә, тузанлы Магнитка урамнары буйлап атлыйлар. Кемдер аларга кызганып, кемдер нәфрәтләнеп карый. Кызганучылар — үзләре кебек үк сөрелгән бәхетсез халык, нәфрәтләнүчеләр — коммунистик идеология белән агуланып өлгергән иреклеләр. Алар бу мескеннәр өстенә төрле гаепләү сүзләреыргыталар, бала-чагалары тоткыннарны таш атып куа.

— Контры!

— Враги социализма!

— Кулаки недобитые!

Магнитка урамнары буйлап ертык сәләмәләргә чорналган татар тоткыннары атлый: муллалар, ишаннар, хаҗилар, Коръән хафизлар, мәгърифәтчеләр, укытучылар, татар байлары, язучылар, галимнәр. Аларны кеше түзә алмаслык тормыштан илләренә качкан өчен төрмә көтә. Тирә-якка явызлыгы белән даны таралган Магнитка төрмәсеннән бу татарларның күбесе чыкмас, аларның каберләре дә билгеле булмас. Могҗиза белән исән калганнарына мәңгегә качкын мөһере сугылыр, алар кара эштән артык күтәрелмәс, күбесе домна мичләрендә янып кибәр.

Асылгәрәй хәзрәтнең Коръәнне яттан белгән су сөлеге кебек сылу кызы Гайшәбикәне дә, кулларын богаулап, Магнитка төрмәсенә озаттылар. Аның бар гаебе туган якка кайтырга теләү иде. Иленнән исә ул мулла кызы булганга сөрелгән иде...

Мәрзия башта апасы яныннан елап йөгереп барды. Аннан сикерә-сикерә талаган этләрдән һәм мылтыклы сакчылардан куркып туктап калды. Апасы аңа үзләре яшәгән баракка кайтырга кушкан иде. Мәрзия көне буе ул баракны эзләде һәм кичен генә таба алды. Әмма алар барагыннан инде күп кешеләр алышынган, алар сәкесендә исә теге исерек урыслар йоклап ята иде. Мәрзия куркып як-ягына каранды, таныш йөзләр эзләде, әмма кешеләр аны әллә танымады, әллә аларда аның кайгысы юк иде — беркем дә Мәрзияне үз янына чакырып алмады. Чөнки барысы да үзләре ач иде. Ә качкан татарларның монда калган туганнарын барысын да барактан куганнар булып чыкты. Аларны хәзер җир асты куышларында яши, диделәр.

Боларны белгәч, Мәрзия елап урамга чыгып йөгерде.

Бу ач далада, таш-тимер арасында аның беркеме дә калмаган иде.

Ул апасының: «Нәрсә булса да, татарларны эзләп тап», — дигән сүзләрен исенә төшерде һәм, елый-елый, җир асты кушларын эзләп китте.

Әти-әнисенең: «Ни булса да, Аллаһтан өметеңне өзмә, аннан ярдәм сора», — дигән сүзләрен хәтеренә төшерде...

Асылгәрәй хәзрәтнең төпчек баласы Мәрзия, Аллаһтан елап ярдәм сорый-сорый, дала буйлап милләттәшләрен эзләп китте...

Фәрештәләр юлдаш булсын аңа...

* * *

Асылгәрәй хәзрәт бистәнең икенче башыннан, цемент заводлары ягыннан ачыклыкка килеп чыкты.

Җитәкләшеп килгән карт белән малайга артык игътибар бирүче булмады, чөнки җәй башында Уралга юынырга төшүчеләр шактый була. Аларны да елгага су керергә бара дип уйладылар. Керерәк як булса да, карт белә торып сулгарак каерды, чөнки Песчаный күпере тирәсен бик нык саклыйлар, ул тирәдә каравылчыларның йөреп торуын белә иде ул. Аның уйларын раслагандай, ул якта чатыр-чотыр ата башладылар, кычкырган, акырган тавышлар ишетелде. Картның йөрәге шашып тибә башлады — нәкъ шушы вакытта анда Маһинур абыстай белән кызлар булырга тиеш иде. Гыйлемгәрәй дә аларга шул тирәдә кушылырга тиеш. Ә анда әнә ду килеп атышалар. Димәк, нидер булган, нидер сизгәннәр сакчылар; кемнедер күргәннәр, шуңа котыралар. Аның гаиләсе башына гына котырмасалар ярар иде.

Солтанхәким дә куркынып калды, әтисенең кулын кысыбрак тотты. Хәзер бу баланың янында анасы да, туганнары да юк, бердәнбер карап торганы — карт атасы. Солтанхәким аның белән, менә шулай җитәкләшеп, дөнья читенә китәргә дә риза. Тик әтисе исән булсын, газапланмасын. Солтанхәким үзе үсеп җиткәч, аны бала караган кебек карар иде, аңа дөньяның бер авырлыгын да күрсәтмәс иде. Тик ул көннәргә хәтле әти-әнисе исән генә була күрсен...

Асылгәрәй хәзрәт яр буйлатып бераз барды да тиз генә каршыдагы куе куаклыклар арасына кереп китте. Исәбе урман эчләтеп барып, килешкән урында Маһинур абыстай белән очрашу иде. Әмма ул тирәдә һаман ату тавышлары ишетелә, буыла-буыла этләр өрә. Урман эченнән исә ярдәм сорап кычкырган, елаган тавышлар ишетелә. Карт сизенеп алды: сакчылар шулай качакларны эзәрлеклиләр һәм тота ба-

ралар иде. Кычкырган, атышкан, өргән, елаган тавышлар бу якка таба якынаялар иде...

Асылгәрәй карт, улы Солтанхәкимне җитәкләп, куаклык буйлап аска таба йөгерә башлады. Тотсалар, эттән талатып үтерәселәре көн кебек ачык иде, аларга эшкә ярамаган карт белән малай кирәкми, сакчылар эшләрдәй кешеләрне генә тотып кире җибәрәләр иде. Хәзрәт, үзеннән дә бигрәк, улы өчен курыкты, чөнки аның улын күрәләтә мондый җәбергә дучар итәргә хакы юк иде.

Юл менә шулай хәвефле башланды...

Әле алар качарга аяк атлап өлгермәделәр, арттан инде куа киләләр иде. Аларның үзләреннән дә алда этләре йөгерә, һәм бу бурзайлардан беркем дә качып котыла алырлык түгел иде. Алай да аларның килеп тотып алуларын көтеп утыру зур ахмаклык булыр иде һәм карт тәвәккәлләргә булды. Юлда ниндидер кечкенә елга очрады, карт, аяк киемнәрен салып, шуның буенча китте, Солтанхәким дә аның артыннан атлады. Бу этләргә аяк эзен буташтыру өчен кирәк иде. Шулай су буйлап бераз баргач, аргы ярга чыктылар һәм ашыга-ашыга урман эченә кереп киттеләр. Хәзрәт Мәһинур абыстайлардан кире якка таба киткәнен белсә дә, башка чара юк иде, күрәләтә этләр авызына барып кереп булмый бит.

Кая таба барганнарын белмәсәләр дә, алар тәвәккәлләп атладылар да атладылар, иң мөһиме — бу тирәдән ераграк китү иде. Ул арада ачыклыклар башланды, аларда анда-санда йортлар, авыллар күренеп тора иде. Әмма Асылгәрәй карт ачыклыкка чыгарга, кешеләргә якын барырга курыкты, чөнки бу авылларның да күзәтү астында булуын чамаларга була иде. Ул, тәвәккәлләп, эчкәрәк керергә булды, тау тирәләрендә барыбер тынычрак булыр кебек тоелды аңа. Карт, кайда урман эчләтеп, кайда су буйлап, шул тауларга карап китте. Эчкәрәк кергән саен, эт өргән тавышлар ерагая барды. Арттан куа килгән сакчылар да, Магнитка торбалары да инде шактый еракта калды. Әмма һәр адымы белән хатыныннан, балаларыннан да ерагая баруын сизенә иде Асылгәрәй хәзрәт, әмма аның башка чарасы юк иде. Тотсалар, аларны үлем көтә иде, ә кече улы Солтанхәкимне котырган этләрдән талатып үтерергә аның хакы юк. Улын коткарып калу хакына Асылгәрәй хәзрәт белә торып кире якка китте, тауларга таба юл алды...

Алар арып, хәлсезләнеп тау итәгенә килеп егылганда, инде кич җитеп килә иде. Куа килүчеләр, сирәк-мирәк авыллар, кешеләр һәм этләр артта, бик еракта калган кебек тоелды. Монда бөтенләй башка дөнья иде. Аяк астыннан челтерәп тау чишмәләре ага, баш очында былбыл кошлар сайрап тора, тирә-якта кара урман шаулый, кыя-таулар басып тора.

Әйтерсең лә кешелекнең әле башланган гына чагы, барысы да саф һәм кыргый табигый хәлдә. Әйтерсең лә моннан кул сузымында гына дөньяны сасытып яткан Магнитка да юк, үлем базлары, пычрак бараклар, мәет белән тулы ач дала да юк. Тере мәеткә әйләнгән коллар да юк. Дөньяда менә шушы Алла биргән бай табигать тә, ата белән бала гына бар...

Менә алар, хәйран калып, тау итәгендәге зур таш ышыгында утыралар.

Алар дөньяда мондый матурлык барын, мондый тынычлыкны инде онытып баралар иде. Яфраклар шулхәтле куе һәм чиста, өсләрендә ник бер тузан бөртеге булсын. Чишмәнең төбендә исә һәр ташны аерым-аерым санарга була, алар баеп барган кояш нурында җем-җем килеп яталар. Карт шул чакта гына күптән инде эчмәгәннәрен дә, ашамаганнарын да искә төшерде. Туктап ял итәргә кирәк иде, чөнки бала да бик йөгәнде, суырылып килде. Кесәдәге сохариларны алып, чишмә суына манчып, утырып ашадылар, бераз ял итеп алдылар. Төн кунарга да шушы тирәдә туктарга кирәк иде, караңгыда кая барганны белмичә барудан мәгънә юк, әллә кайларга барып чыгуың бар. Солтанхәким дә бик арыган, ашагач, бөтенләй изрәп китте, утырган урынында йоклый башлады. Шуңа күрә, тәмам караңгы төшкәнче, Асылгәрәй карт төн кунар өчен җайлырак урын эзләргә булды.

Туктаган җирдән ерак түгел ул бик зур һәм коры тау куышы тапты. Ул әйтерсең лә алар өчен алдан әзерләнеп куелган иде.

Карт, шырпы сызып, бу хикмәтле мәгарәнең эчен яктыртып карады, җәнлек-мазар булмасын дип уйлады. Тау куышы буш иде, әмма анда кайчандыр кешеләр яшәгәнлеге ярылып ята. Ул арада әтисе артыннан Солтанхәким дә килеп җитте, ул да, гаҗәпләнеп, тау эчендәге бу таш йортны күзәтте. Бу, чыннан да, зур өй иде, әнә чит-читләрендә таштан сәкеләргә хәтле сакланган, уртада учак урыны беленеп тора. Әмма иң сәере — стеналарга чокып ясалган рәсемнәр иде. Анда зур-зур җәнлек сурәтләре, филгә охшаган йонлач җанварлар, кыргый атлар, аларны куа килгән озын-озын кешеләр. Карт тагы шырпысын сызып карады — каршы стенада йолдызлы күк йөзенең рәсемен, ташка уелган ай белән кояшны күрде. Ул үзләренең борынгы кешеләр яшәгән мәгарәгә килеп чыгуларын аңлады. Мондый рәсемнәрне ул Төркиядә һәм Мисырда күргән иде инде.

Гаҗәпләнүдән йокысын да оныткан Солтанхәкимгә ул борынгылар турында үзе белгәннәрне аңлатты, тарих буенча бу тирәдә туфаннан соң беренче кешеләрнең яшәвен әйтте. Әлбәттә, башка заманнар булса, ул аңа китаплар буенча күбрәк тә сөйли алган булыр иде, әмма Асылгәрәй картның

уенда хәзер бер генә нәрсә — качу иде. Башка заманнар булса, ул, гыйлем иясе, бу урманнарда каңгырып йөрмәс тә иде, Солтанхәкимнең дә урыны башка җирдә булыр иде. Төпчек улын ул, һичшиксез, йә Төркиягә, йә Мисырга укырга җибәргән булыр иде. Солтанхәким, анда динне һәм тарихны өйрәнеп, зур галим булып, милләтенә хезмәт итәргә кайтыр иде. Ә хәзер бу баланы бу динсезләр илендә нәрсә көтә? Мәңгелек сөрген көтә аны монда, аңа инде хокуксыз дип мөһер сугылган, аны биредә укырга да алмаячаклар, үзе теләгәнчә яшәргә дә ирек бирмәячәкләр. Димәк, җай чыкса, Магниткадан гына түгел, бу илнең үзеннән дә башны алып качарга кирәк...

Яңадан урамга чыгып, чишмә суында тәһарәтләнеп алдылар, кыйбланы эзләп табып, кичке намазларын укыдылар. Бу бәлаләрдән исән-сау котылган өчен Аллаһка рәхмәт әйттеләр. Иң мөһиме — бүген алар исән иде, бүген алар иректә иде, бүген алар сау иде. Аллаһ насыйп итсә, гаиләләре белән дә яңадан очрашасыларына алар чын күңелдән ышаналар иде. Шул ышаныч аларны Урал тауларының кырык сырты аша ерак юлга алып чыккан иде.

Чыршы-нарат ботаклары җыеп алып кереп, тау куышына түшәделәр. Мәгарә авызын зур гына таш белән эчтән капладылар.

Башларын кыйблага куеп, бер-берләренә сыенып, ата белән ул төнге йокыларына киттеләр. Күктән фәрештәләр иңеп, алар йоклаган тау куышын әйләндереп алдылар, бу тирәдән җен-пәриләрне кудылар. Намаз ияләренең төнге йокысын, Аллаһның әмере белән, фәрештәләр саклап тора иде. Беркем дә аларны, аякларыннан сөйрәп, эшкә куып чыгармый, кулларына көрәк биреп, тирән котлованнарга куып төшерми, беркем кыйнамый, ирексезләми. Адәм баласы үзенең табигый хәлендә, табигать кочагында бер төн булса да үзе теләгәнчә яши иде.

Асылгәрәй картның юлында очраган бу беренче тау сырты Кырыктау дип атала иде. Урал тавының көньяк-көнчыгышында, кыйбла якка карап сузылып яткан бу сырт дала белән тау арасында чик булып тора. Бу яктан юлга чыгучылар өчен ул — беренче, Уралның теге ягыннан килүчеләр өчен соңгы сырт иде. Бу тау куышында исә моннан йөз мең ел элек булган бозлык чорында кешеләр качып сакланып калган. Ян-яктагы таш сәкеләр, уртадагы учак урыннары, стенадагы борынгы рәсемнәр — барысы да алардан калган. Ул кешеләр үзләре исә бирегә туфан суыннан качып килеп чыкканнар, Урал таулары аларны үзенә сыендырган. Ул кешеләр зур гәүдәле, алып адәмнәр булганнар, таудан тауга атлап кына йөргәннәр. Моннан кырык мең ел элек исә алар, Урал

тауларыннан төшеп, ике тарафка таралганнар — көнчыгышка һәм көнбатышка. Шуннан инде бөтен дөньяга.

Асылгәрәй карт белән Солтанхәким адашып менә шул борынгы тау куышларының берсенә килеп чыкканнар иде.

Бу тирәләр чын мәгънәсендә үзендә мәңге ачылмаган зур серләр һәм хикмәтләр саклый иде.

Әгәр сорарга кеше булса, Асылгәрәй карт биредәге һәр тауның, һәр сыртның, һәр елга-күлнең, күпчелек авылларның искедән татарча исемнәр белән аталуын белер иде. Биредә, Нух пәйгамбәр заманнарыннан калган тау араларында, үзләрен борынгыдан типтәр яки мишәр дип атаучы татарлар яшәп ятуын күрер иде. Әмма бүген Асылгәрәй карт үз милләттәшләреннән дә качарга мәҗбүр, чөнки ул белә — бу җирләргә хәзер ул татарлар хуҗа түгел, әнә теге атлы сакчылар хуҗа. Яәҗүҗ-мәәҗүҗ кавеме, Шишкаловлар өммәте хуҗа. Әнә алар, тау-ташларны дуңгыз кебек актарып, биредән алтын-көмеш, яшьмә эзлиләр, мәрмәр, тимер чыгаралар, тиздән уранга да барып җитәчәкләр. Асылгәрәй картның аяк очыннан гына агып яткан Орчык елгасында исә алтын бар, ә янәшәдәге Ярлык авылы янында алтын казылмалары таралып ята.

Әнә биредән ерак түгел Ниязкол һәм Күчем авыллары, анда яшьмә ташлары хәтта җир өстендә аунап ята, иелеп ал гына. Урман эче булса да, тирә-якны тирән күлләр бизи: Мулдак, Атаулы, Карабалыклы, Чуртанлы, Чибәркүл. Аларның шифалы ләмнәре белән биредә яшәүче татарлар гомер буе дәваланганнар, чишмәләренең тере суын эчеп, дәрман алганнар. Шушы күл буйларында, тау битләрендә, урман араларында, сирәк очрый торган затлы таш кебек, татар авыллары сибелеп киткән. Самар, Юлдаш, Ишкул, Дәүләтша, Булат, Гаскәр, Кучкар, Хөсәен, Үзән, Шәрип авыллары. Алар тирәсеннән бормаланып Кызыл, Янгил, Ташимер, Сакмар сулары агып ята, шушы тау сыртларыннан татарның ике бөек елгасы — Агыйдел һәм Җаек башлана. Милләт тормышы башлана...

Ерак түгел шаулап агып яткан Дарулы елгасыннан исә татарлар гомер буе алтын юдырган. Хәер, Октябрь инкыйлабына хәтле бу тирәләрдә татар Рәмиевләрнең дә алтын базлары булган бит, шул алтын бәрабәренә алар мәчет-мәдрәсәләр тотканнар, китап-журналлар чыгарганнар, милләткә хезмәт иткәннәр. Чыгышлары белән Зәйтуган авылыннан булган бу асыл татарлар соңыннан кайсы ачтан, кайсы совет төрмәләрендә үлеп беткән. Алар йөргән юллардан хәзер авылдашлары Асылгәрәй хәзрәт һәм аның улы Солтанхәким килә. Җитмеш елдан соң бу тирәләрдә мәчет-мәдрәсәләр тотачак Солтанхәким килә...

Икенче көнне аларны кошлар сайрап, чишмәләр җырлап, урман шаулап уятты.

Аларның күптән инде мондый матурлыкны, сафлыкны күргәннәре юк иде.

Монда яшәүче кешеләр нинди бәхетлеләрдер — көн саен шушы гүзәллекне, шушы тауларны, урманнарны, саф чишмә-суларны күрәләр. Алар моннан кул сузымында гына Магнитка дип аталган җәһәннәм чокыры барлыгын белмиләрдер дә әле. Һәм белмәсеннәр дә. Кеше бу кыска дөньяга газап өчен түгел, бәхет өчен туган бит, менә шушы бушка бирелгән байлыкның, матурлыкның кадерен белеп яшәү өчен туган. Элек ул шулай булган да, татар халкы бу тауларны, бу матурлыкны, бу байлыкны мең еллар буе саклый алган. Әмма хәзер биредә башка затлар хуҗа, аларга матурлык түгел, бер көнлек байлык кирәк. Бу бәндәләр өчен дөньяның да, кешенең дә кадере юк.

Әсирлектән котылгач, бу ике дөньяның аермасын Асылгәрәй карт бигрәк тә ачык сизде. Унике яшьлек Солтанхәким дә, андагы һәм мондагы хәлләрне чагыштырып, хәйран калды. Үлән ашап булса да, ул шушы җирдә, шушы матурлык арасында калырга риза иде. Ә үләннең биредә нинди генә юк — әнис һәм какысы да, җиләк яфраклары да, бөтнеге, балтырганы да. Чыршыларыннан сап-сары сагызы тамып тора, салкынча урында үскән каен агачларыннан әле татлы суы агып тора. Ул чишмә суларын инде әйтерлек тә түгел — берсеннән-берсе тәмле, аны эчкәч, ашыйсы килү дә онытыла.

Намазлар укып, ашап-эчкәчтен, тагы юлга кузгалдылар.

Асылгәрәй карт инде туп-туры тауларга каршы барырга булды.

Артка юл юк, анда төрмә һәм сакчылар, котырган этләр өере куа килә иде.

Солтанхәким, яшь тай кебек, әтисенең әле алдына, әле артына чыкты, һәр үләнне, һәр ташны тотып карады, дөньяга соклануыннан нишләргә белмәде. Мондый биек таулар хәтта Зәйтуганда да юк иде. Аларның кайберләренең башында хәтта кар да эреп бетмәгән, бәлки, ул беркайчан эремидер дә. Кызык, тауларның кайберләре гел таштан, кайберләре агачтан, урманнан тора. Солтанхәким аларның барысына да менәр микән, аларга аю-бүреләр очрар микән? Әтисе аларны ничек җиңәр икән?

Ә Солтанхәкимнең әтисе аю-бүре турында түгел, алга таба юл һәм ашау турында кайгырта иде. Юлын ул кояш баешына карап тотарга булды, туган җир шул якта иде. Ә менә ашау мәсьәләсен алдан кайгыртырга кирәк булачак, бу каткан ипи озакка бармас. Юлда кош-корт аулап йөрергә аның вакыты да, мөмкинлеге дә юк, ә үлән белән ерак китеп бул-

мас. Ачыклыкларда күренеп-күренеп киткән авылларга сугылыр идең, эзгә төшүләре бар. Анда кемнәр яшәгәнен белеп булмый, тотып бирүләре дә бар, хәзер шундый заман. Инде берничә көн ничек тә түзәргә кирәк, эчкәрәк кергән саен, сакчылар ерагаер, качакларны аулап йөрмәсләр. Ул вакытта авылларга да кермичә булмас, бу хәтле юлны бала белән ач үтеп булмас.

Ата белән бала, шактый көч куеп, Кырыктау сыртының түбәсенә менеп җиттеләр.

Карт ял итәргә туктады һәм тау башыннан тирә-якка карады.

Артта, шактый еракта, кап-кара таш-тузан эчендә, Магнитка төтенләп ята иде. Биредән ул бигрәк тә котсыз һәм килбәтсез булып күренә, дәһшәтле һәм җансыз булып тоела. Ул тирәдә ник бер яшеллек, ник бер матурлык чыганагы булсын — анда барысы да кара төстә. Шушы җансыз таш-тимер арасына килеп кысылган Урал суы гына, кая барып бәрелергә белмичә, кызыл ярларында газаплана. Кайчандыр үзләренең дә шунда яшәп ятуларына ышанасы килми, бу хәлләр куркыныч төш кебек кенә тоела...

Карт көнбатышка таба борылды.

Анда офыкка хәтле тау сыртлары тезелеп киткән иде.

Берсе бетә, икенчесе башлана.

Икенчесе бетә — өченчесе, дүртенчесе, бишенчесе...

Офыкларга хәтле сузылган кырык сырт. Алар, дулкын-дулкын, киртләч-киртләч булып, карт белән малай алдында диңгез кебек тибрәнәләр. Аста, алар арасында, киң үзәнлекләр, тирән елгалар, эреле-ваклы авыллар. Авыл яннарында урман төпләп ясалган басу-кырлар. Алары бик аз, чөнки монда бөтен җирдә таулар хуҗа, таулар хаким. Һәм Асылгәрәй картка улы Солтанхәким белән берлектә аларны җиңәргә, шушы кырык сыртны кичәргә кирәк. Туган җиргә, туган туфракка кайтып егылу өчен язмышның кырык сыртын үтәргә кирәк булачак.

Кайда — үлән, кайда агач кайрысы кабып, кайда кипкән сохарины кимереп, адым саен туйганчы чишмә суы эчеп, тагы бер көнлек юл үттеләр. Таулар ерактан гына бер-берсенә якын кебек тоелсалар да, бара башлагач, аралары шактый ерак икәнлеге беленде. Асылгәрәй карт гел урман тирәсеннән, агачлар арасыннан барырга тырышты. Бу юлы төнлеккә тау куышы очрамады, чокыр кебек бер урынга кереп, бөгәрләнеп йокладылар. Әллә кайдан гына болыт килеп чыгып, шаулап яңгыр явып үтте. Әчтә җылы ризык булмаганнан болай да өшегән тән бөтенләй туңды, калтырата ук башлады. Җәй башы булса да, тауларда төннәр салкын була икән, бу төндә алар шунысын да аңладылар...

Өченче көнне Солтанхәким күзгә күренеп хәлсезләнде, аруы, авыруы йөзенә чыкты. Ул туктаусыз йөткерә башлады, ә үзенең бит-куллары ут булып яна иде. Җитмәсә, кичәге болыт, тагы әйләнеп килеп, боз коеп китте, көн шунда ук суытып җибәрде, аяк асты йөреп булмас хәлгә килеп лычкылдады. Качакларның да өс-башлары лычма булды, чабаталары өзелеп, тетелеп чыкты. Туктап ял итмичә, кипшенмичә, алга таба юлны дәвам итү мөмкин түгел иде. Арттан чакка атлап килгән Солтанхәким белән дә нидер эшләргә кирәк, баланың бөтенләй өзлегеп, өзелеп куюы бар...

Карт, ярдәм көткәндәй, биек тауларга карады, әмма алар бу юлы аеруча дәһшәтле һәм кырыс иделәр. Асылгәрәй карт, эчкә кергән саен, тауларның да килеш-рәвешләре үзгәргәнлеген аңлады. Беренче сыртлар әле тәбәнәгрәк, агачлырак булса, алга таба инде аның юлында түбәләре күккә тигән кара ташкыялар басып тора иде. Кайберләренең түбәсен кар каплаган, аларга якын килерлек тә түгел. Уралтау бу карт белән малайны үзенә артык якын китерергә теләми дә иде, ахрысы...

Тау итәгеннән бер ышыграк урын эзләп табып, карт учак ягып җибәрергә коры-сары эзләштерә башлады. Карагайчыршы төпләренә яңгыр үтмәгән, анда узган елгы ботак-саташклар шактый иде. Асылгәрәй карт, аларны тиз генә җыештырып, учак ягып җибәрде, бөтенләй хәлсезләнгән улын җылыгарак китереп утыртты. Хәзер ничек тә балага җылы азык әзерләп ашатырга кирәк иде, һәм картның бөтен өмете елгада, елгадагы балыкта иде. Суда, әлбәттә, балык бардыр, әмма аны ничек тотасың? Бәлки, бала чактагы кебек, күлмәк белән сөзеп карарга кирәктер, су буенда ачка үлеп булмый бит инде. Тота алса, таш өстендә кыздырып булса да, улына җылы ризык ашатыр иде. Шул ният белән карт якында гына шаулап агып яткан киң суга төште.

Елга шактый сай булып, төбендәге ташларына хәтле ялтырашып яталар иде. Асылгәрәй карт болай да юеш күлмәген салып, бала чактагы кебек изү-җиңнәрен бәйләп, суга салды. Үзе, аяк-куллары белән суны шапылдатып, күзгә күренмәгән балыкларны күлмәккә таба куа башлады. Читтән караганда, малай-шалай кебек кыланган ак чәчле бу карт бик сәер күренә иде, әмма аның башка чарасы юк иде. Бераздан ул суга салган күлмәген тартып чыгарды, әмма анда бернәрсә дә юк иде. Карт күлмәген тагы, ташлар белән бастырып, су төбенә салды, бер читеннән тотып, аңа тагы балык куа башлады... Күлмәк бу юлы да буш булып чыкты, аның төбенә елга ташлары гына тәгәрәп кергән иде. Карт соңгы өмет белән күлмәген тагы су эченә ташлады, кул-аяклары белән шапылдатып, аңа тагы балык куа башлады. Бераздан аңа капчык төбендә нидер

бар кебек тоелды, ул аны ашыгып тартып алды һәм, балык эзләп, кулын тыкты. Әмма анда вак таштан кала берни юк иде. Асылгәрәй карт, әрнеп, учындагы ташларны суга атмакчы булды, әмма кояшта ялтырашып яткан сары бөртекләрне күреп туктап калды. Ул аларны күзенә якынрак китереп карады, бармакларына алып капшады. Шик юк, аның учында алтын бөртекләре җемелдәшеп ята иде…

Карт, куркып, як-ягына каранды.

Бу тирәдәге елга-суларда ул алтын барлыгын ишетеп белә иде. Әмма алтынга аучылар да күп була шул, алар берберләрен үк үтереп бетерәләр. Менә бит, балык эзләгәндә алтын тапты, әмма бу хәл Аллаһның рәхмәте дә, сынавы да булырга мөмкин иде. Шуңа күрә, вакыты җитмичә, карт ул алтынга кагылмаска булды, бер чүпрәк кисәгенә төреп, аны кесәсенә тыгып куйды. Хәзергә аңа алтынга караганда ашау кадерле иде, чөнки учак янында ризык көтеп авыру улы ята, аны тизрәк аякка бастырырга кирәк. Чөнки бу хәлдә алар юлларын дәвам итә алмаячаклар, монда озак тоткарланырга да ярамый, сакчыларның бу тирәгә килеп чыгулары бар.

Аның уйларын раслагандай, елганың өске агымында, текә борылыш артындагы урманлыкта, сәер тавышлар ишетелде. Асылгәрәй карт, колагын салып, тын да алмый тыңлап тора башлады. Анда кемдер бар иде. Хайванмы, кешеме? Чөнки бу тирәдә язгы йокыдан уянган ач аюлар да бар, дип сөйлиләр, өскә килеп чыга күрмәсен. Карт тизрәк улы янына китәргә ашыкты, әмма шулчак колагына ниндидер көй ишетелгән кебек булды. Чү, татарча җырлый бит бу бәндә?! Димәк, анда, агачлар артында, кеше бар һәм ул татар кешесе. Карт, әсәрләнеп, тагы тыңлый башлады. Бу җыр аңа бөтенләй таныш түгел, әмма татар телендә иде…

Шул көй артыннан карт елга борылышына менеп китте, агачлар арасыннан башын тыгып, сак кына көй ишетелгән якка карады. Анда Асылгәрәй карт яшьләрендәге бер ир-ат сай суда нидер эшләп маташа иде. Аның кулында он иләге кебек нәрсә, ул, аны як-якка селкетеп, нидер эшли, нидер эзли иде. Суга чумырып ала да тагы или, тагы эзли, вак ташлар арасында бармаклары белән актарына.

Асылгәрәй карт сизенеп алды — бу ир-ат алтын эзли иде…

Алтын юдыра. Әмма, иләген чумырып алган саен, берни тапмый, ташларны кире суга томыра. Үзе борын астыннан гына һаман көйли, һаман җырлый:

Учларымда гына, һәй, минем күмер,
Янып сүнгән күмер, ләй, безнең гүмер.
Урал тауларында гына, ләй, кырык сырт,
Урал тауларына үпкәләмим,
Язмышкайларымда гына, ләй, бәхетем юк…

Алтынчы карт, иләген суга чумырган саен, шушы җырны башлый. Бармаклары белән иләк төбендә актарынганда, бераз туктап тора, аннан өр-яңадан тагы шушы җырны сузарга тотына. Кем булыр ул — алтын эзләп йөрүче берәр угрымы, әллә алар кебек бу тирәдән үтеп кенә баручы качакмы, яки мондагы берәр авыл кешесеме? Аңа күренергәме, әллә сиздерми генә үтеп китәргәме? Китәр идең, авыру Солтанхәким анда ашарга көтеп ята, аңа ярдәм кирәк. Бәлки, бу татар кешесен кара урман уртасында Аллаһы Тәгалә аларга ярдәм итәр өчен җибәргәндер? Бу дөньяда очраклы бернәрсә дә юк бит, бәлки, тәвәккәлләп эндәшеп карарга кирәктер?

Асылгәрәй карт агач арасыннан бер-ике тапкыр тамак кырып куйды, аннан әкрен генә чыга башлады. Алтынчы карт иләген тизрәк суга ыргытты, чөнки ул белә: тотсалар — эш харап. Алтын хөкүмәтнеке санала, аңа кагылырга ярамый, тапсаң да, хөкүмәткә илтеп тапшырырга кирәк. Юк икән, әнә Магнитка төрмәсе көтә, алар авылыннан күпләр шунда юкка чыкты инде. Хөкүмәт сизмичә калса да, карак-угры талап, үтереп китәргә мөмкин. Хәзер бу тирәдә алар бик күп, Әтрәчтә төзелеш башланганнан бирле, урман качак белән, сукбай белән тулды. Кемнән нәрсә көтәсен дә белеп булмый...

— Әссәламәгаләйкүм, туган, — дип эндәште аңа Асылгәрәй карт, үзенең кемлеген сиздерәсе килеп.

— Вәгаләйкүм, вәгаләйкүм, — дип җавап бирде алтынчы карт, әле һаман нидәндер шикләнеп.

— Син миннән курыкма, туган, — дип, аны тынычландырырга ашыкты Асылгәрәй карт. — Мин синең кебек үк бер карт, Алла бәндәсе. Бу тирәдән үтеп кенә барышым. Җырыңны ишеттем дә түзә алмыйча чыктым. Күптән үзебезчә көй ишеткән юк иде.

Алтынчы карт шунда ук аңлап алды — аның алдында Магнитка качагы басып тора иде. Өстендә тетелеп беткән кием, чабаталары тишек, йөзен сакал-мыек баскан. Хәзер күп алар бу тирәдә.Ә монда аларга карата закон каты, шулар аркасында авылны да гел тикшереп, тентеп торалар. Кем килгән, кем киткән, кем кайда качып ята, кем качырып яткыра — барысын да барлыйлар. Тотсалар, качучыга да, качыручыга да төрмә. Шуңа күрә авыл халкы бу качакларны хәзер якын да җибәрми, өенә кертми, беркемнең дә алар өчен төрмәдә утырасы килми.

— Тегеннәнме? — диде алтынчы карт, башы белән Урал аръягына изәп.

Асылгәрәй карт ялганлый алмады, башын гына какты.

— Кече улым белән, — диде ул, тавышын әкренәйтә төшеп. — Бала авырып китте менә, бара алырлык түгел. Аңа

ризык юнәтә алмаммы дип, елга буена төшкән идем, булмады.

Алтынчы карт, агач арасыннан чыгып, сай суда йөзеп йөргән иләген барып алды, аны тиз генә капчыгы төбенә шудырды.

— Монда балык юк, суы артык каты ага, — диде ул, Асылгәрәй картны астан гына күзәтеп.

— Ашарга бирәр нәрсә юнәтеп булмасмы икән, туган? — диде Асылгәрәй карт, тизрәк үз гозерен әйтеп. — Мин сине буш итмәс идем. Бала ач анда, өч көн җылы ризык капканы юк.

Алтынчы карт, аның «буш итмәм» дигән сүзләренә бик ышанып җитмәсә дә, баласын кызганып куйды. Карт тәртипле күренә, карак-фәләнгә охшамаган, советлар өеннән куып чыгарган бер бәхетсез, ахры. Алар күп монда хәзер, бөтен тау аралары шуларның мәете белән тулган. Нинди заманнар җитте бит, адәм баласының чебен кадәр дә кадере юк.

— Мин сиңа бушлай да ярдәм итәр идем, кордаш, — диде ул әкрен генә. — Әмма монда тикшерү бик көчле. Сезнең халыкны авылга якын да җибәрмиләр, качакларга ярдәм иткәнеңне белсәләр, үзеңне утыртып куялар. Авылдан ничә кеше Магнитка төрмәсендә ята хәзер шуның өчен…

— Аллаһ ризалыгы өчен, бер җаен тап, туган, — диде Асылгәрәй карт, нишләргә белмичә. — Без анда барып күренеп йөрмәбез. Син мондагы кеше булгач, бир бер киңәш, бала кызганыч бит. Буш итмәм мин сине, валлаһи…

Шулай диде дә Асылгәрәй карт, кесәсеннән алтын салынган төенчекне тартып чыгарды.

— Мә, үзеңә кирәк кадәр ал, тик ярдәм генә ит, — диде ул, төенчекне алтынчы картка таба сузып.

Алтынчы карт, төенчекне алып, күзенә якынрак китереп карады, сары бөртекләрне кытыршы бармаклары белән угалады.

— Мә, бу сиңа кирәк булыр әле, — диде ул, төенчекне кире Асылгәрәй картка биреп. — Юлың ерак булырга охшаган, кирәге чыгар. Әмма теләсә кем алдында чыгарма моны кесәңнән, башыңа җитүләре бар.

— Алайса, мин сиңа ул алтынның чыккан җирен күрсәтим, — диде Асылгәрәй карт.

Алар яр буйлап аска таба төшеп киттеләр.

— Менә шушы урында күлмәк белән балык тотарга уйлаган идем, алтын килеп чыкты, — диде Асылгәрәй карт, борылышны узгач. — Тик елга төбен бераз кузгатырга, болгатырга кирәк. Мин улым янына киттем, кордаш, урынсызга борчыган булсам, гаеп итмә.

Шулай диде дә Асылгәрәй карт, учак янына китте.

Алтынчы карт та дәшми генә аңа иярде.

Юлаучы картның эчкерсезлеге, баласы хакына соңгы алтынын чыгарып бирүе, ике дә уйламыйча байлык тапкан җирне төртеп күрсәтүе аны тетрәндерде. Мондый ихлас, киң күңелле кешеләрне аның инде күптән күргәне юк иде. Үзе бик гыйлем, укымышлы зат булырга охшаган, дин кешесе, ахры... Алтынчы карт, ни булса да, бу ихлас юлаучыга булышасы итте һәм аның артыннан иярде.

Алар килеп җиткәндә, Асылгәрәй карт яндырып киткән учак инде сүнеп бара, ә аның янында аңсыз хәлдә Солтанхәким ята иде. Аның хәле бер дә җиңеләймәгән, киресенчә, тагы да авырая төшкән кебек. Бала туктаусыз саташа, әле әнисен, әле әтисен чакыра, туганнарына эндәшә, алар белән сөйләшә иде...

Асылгәрәй карт аңа тизрәк кружка төбендә калган суны эчертте, ашарга эзләп, кесә төпләрендә кармаланды. Әмма анда, ипи валчыгыннан кала, берни юк иде. Моны күреп, алтынчы карт тизрәк кесәсенә тыгылды, аннан берничә пешкән бәрәңге, йомырка, күсәмәсе белән ипи, тоз тартып чыгарды һәм качаклар алдына куйды. Бу хәтле нигъмәтне күргәч, инде берничә көн ачлы-туклы йөргән Асылгәрәй картның башлары әйләнеп китте, күзләренә яшь бәреп чыкты. Болай булгач, улы ачтан үлмәячәк иде, иншаллаһ...

— Рәхмәт, кордаш, — диде ул, күз яшьләре өчен уңайсызланып. — Баламны ач итмәдең, Аллаһ үзеңне дә гомерлек ризыклы итсен...

Бу хәтле зур һәм изге сүзләрдән алтынчы карт әллә нишләп китте, аның катып барган күңеле нечкәрде. Агач төбендә авырып яткан бу бала аңа егерме беренче елны ачлыктан үлгән үз балаларын исенә төшерде. Ул елларда үзе төрмәдә утырып калды, ә ачлык аның бөтен гаиләсен кырып салды. Һәм менә дөньяда тагы шул хәлләр кабатлана, тик инде башка кешеләр белән...

Күзенә килеп тыгылган яшьләрне күрсәтмәс өчен, алтынчы карт тизрәк учакны тергезеп җибәрде, чәй кайнатырга куйды. Асылгәрәй карт исә улын ашатырга ашыкты. Хәле бик авыр булса да, Солтанхәким ризыкка битараф кала алмады, ачлык авыруны да җиңде, малай, башын калкытып, әтисе биргәнне кабарга мәҗбүр булды. Аның маңгаена эре тир бөртекләре бәреп чыкты, бераз капкалагач, ул яңадан күзләрен йомды, яңадан онытылды...

— Улыңның хәле, чыннан да, авыр икән, кордаш, — диде алтынчы карт, учак янына чүгәләп. — Моның белән Уралтауны кичә алырсың микән? Ай-һай. Бу тирәдә әле ачыклыклар, юллар бар, алга таба тау өстендә тау, сырт өстендә сырт бит. Кайсы якка кайтып барышың соң?

— Татарстанга, Бөгелмә, Шөгер тирәләренә... Җиде бала

белән, мулла булган өчен сөрделәр. Өчесе бу җәфадан үлде инде. Калганнары да харап булып бетмәсен дип, качарга булдык. Башта ук аймыл булып беттек, хәзер аларның да хәлен белмим, кайсы якка киткәннәрдер...

— Бу тирәдә әле юллар бар — Баймак ягына да, Ырынбур далаларына да. Әмма анда күзәтү көчле, чөнки ачык урын, качкан кеше ул якка китми, тәвәккәлләп тау арасына керә. Әмма белмәгән кешегә анда, ай-һай, кордаш... Бигрәк тә бу авыру бала белән...

Ул арада чәй кайнап чыкты, аңа үлән яфраклары тутырып, Солтанхәкимгә эчерделәр. Бала бер-ике йотты да тагы күзләрен йомды. Әллә ул йокыга китте, әллә тагы аңсыз ята — белеп булмый иде. Алтынчы картны ялгыз калдырып, Асылгәрәй хәзрәт намаз укып алды, бер Алладан улы өчен сәламәтлек сорады, аның тизрәк аякка басуын теләде. Бала чагында гына бер-ике ел авыл мәдрәсәсенә йөргән алтынчы карт өчен аның бу намазы шаккатыргыч булып тоелды. Үзләре кара урман уртасыннан качып баралар, ашарларына юк, юлны белмиләр, җитмәсә, малае авырып киткән, ә намазын калдырмый. Инде өч баласы бу хәлләрдән егылып үлгән, калганнарының кайда икәнлеген белми, ә намазын барыбер калдырмый, барыбер Алладан өмет итә. Алтынчы картның мондый кешеләрне күптән күргәне юк иде инде, алар ягында хәзер дин бетеп бара, барысына совет бандитлары хуҗа.

— Башка вакыт булса, мин сезне авылга гына алып кайтыр идем, туган, — диде ул, бу диндар картканиндидер яхшылык эшлисе килеп. — Әмма тотачаклар. Монда этләр белән көнаралаш тикшереп китәләр, бигрәк тә җәйгә чыккач.

— Авылыгыз зурмы соң?

— Заманында шактый зур иде. Без монда бик борынгыдан яшибез, бабайлар әйтмешли, Нух пәйгамбәр заманыннан бирле. Мишәр токымыннан без. Авылда заманында мәчет-мәдрәсәләр дә бар иде, советлар барысын да бетерде. Аларга дин кирәк түгел бит. Алар нәрсә кирәген үзләре дә белми.

— Үзеңнең гаиләң зурмы соң? — дип сорады Асылгәрәй карт сак кына.

— Берьялгызым мин, — диде алтынчы карт, аны гаҗәпләндереп. — Безнең ярты авыл ачлык елны кырылды, минекеләр дә шунда үлеп бетте. Үзем төрмәдә калдым ул вакытта, ректә булсам, күрәләтә ачтан үтермәс идем, бер җаен табар идем...

— Төрмәгә нәрсә өчен утыртканнар иде соң?

— Ул вакытта шулай иде бит — аклар килеп, кызыллар яклыларны аталар, кызыллар килеп, аклар яклыларны асалар. Мин ак та түгел, кызыл да түгел, читтә үз көнемне үзем күрүче бер зимагур идем. Берсенә дә баш бирмәдем, буйсын-

мадым, шуның өчен утыртып та куйдылар. Үзем яннарында булсам, балаларымны ачка үтерә торган ир түгел идем мин. Менә шулай, туган, син хәзер күргәннәрне мин күптән үз башымнан кичердем инде.

Алар шактый вакыт тын гына утырдылар.

Бу тынлыкны чатыр-чотыр учак янганы һәм Солтанхәкимнең авыр итеп сулыш алганы гына боза иде.

— Авыллар бик үзгәрде хәзер, туган, — дип дәвам итте алтынчы карт. — Кулак дип, бөтен хәлле кешеләрне Магниткага сөрделәр, кайберләре үзләре язылып китте шул җәһәннәмгә. Чөнки авылда да хәзер тормыш җиңел түгел. Әллә ниткән колхозлар уйлап таптылар, бөтен мал-туарны җыеп алып чыгып киттеләр. Колхозларында эш бармый, бездә бит җирләр аз, кругом урман-тау. Бу якларда ничә ел рәттән корылык булды бит, халык тагы ачлыктан кырылды. Магниткадан җыен угрының килеп, талап киткән очраклары да булды, анда да теләсә кем бит хәзер. Шуңа күрә хәзер халык авылга беркемне кертми, беркемгә ышанмый, туган.

— Үзең колхозга кердеңме соң? — дип сорады Асылгәрәй карт сак кына.

— Мине авылда Зимагур Булат дип йөртәләр, — диде алтынчы карт көлемсерәп. — Ә чын исемем Тимербулат минем. Колхоз дип, миңа якын килергә куркалар, чөнки беркайчан да уртак сукага җигелмәсне беләләр. Барыбер колхозга талыйлар, дип, артык мал-туар да тотмыйм, бер кәҗәм дә берничә баш сарыгым бар, аннан тавык-чебеш, каз-үрдәк. Миңа җитә...

Ике карт шулай шактый вакыт сөйләшеп утырдылар.

Аларның бер-берләренә серләре сыя иде.

Асылгәрәй карт аңа авылдан ничек сөрелүләре турында, Магниткада күргәннәре хакында сөйләде. Тимербулат карт этле сакчыларның ничек котырулары, өй саен кереп, тентеп йөрүләре турында әйтте. Адәм баласына, бигрәк тә мөселман-татар халкына, бер җирдә дә тыныч кына яшәргә көн юк иде.

— Алайса, болай итик, хәзрәт, — диде Тимербулат карт, аны олылап. — Сез бу урыннан кузгалмагыз, бүген авыл тирәсендә иртәдән бирле теге этләр йөри. Мин үзем кичке якта бу тирәләрне тагы бер урармын. Бераз җылы ризык пешереп китерермен. Бу балага яхшы тәрбия кирәк хәзер, үпкәсендә булмагае, ут булып яна бит. Син мин килгәнне көт.

— Рәхмәт, Тимербулат туган, — диде Асылгәрәй карт, күңеле нечкәреп. — Үзеңә зыян килә күрмәсен, берүк сак бул. Аллаһы Тәгалә сиңа юлдаш булсын.

Алтынчы карт, капчыгын алып, урман эченә кереп югалды. Һәм тирә-юнь тагы тып-тын калды...

Әйтерсең лә ул карт булмаган да, әйтерсең лә төштә, хы-

ялда гына чагылып үткән. Әмма әнә табында ул калдырып киткән ризыклар өелеп тора, урман ягыннан тагы аның моңлы тавышы ишетелә:

Урал тауларында гына, ләй, кырык сырт,
Урал тауларына үпкәләмим,
Милләт тарихында, ләй, кырык сырт...

Асылгәрәй карт хәзер генә бу җырның хикмәтенә төшенгән кебек булды. Әйе, милләт тарихы да бик катмарлы, татар халкына, исән калу өчен, фаҗигаләрдән торган кырык сыртны үтәргә кирәк булган икән. Хәзер исә Асылгәрәй хәзрәт шушы юлда. Исән калу өчен, иманын һәм кешелеген саклап калу өчен, аңа шушы кырык сыртны кичәргә кирәк. Аллаһ бу авыр юлында менә шундый яхшы бәндәләрен насыйп итсен инде...

Әйе, дөньяда яхшы кешеләр бетмәгән шул, шөкер...

Бу яңа режим ничек кенә кешеләрдәге иманны һәм әхлакны суырып алырга, юк итәргә тырышса да, яхшылыкның әле тамырлары тирән. Милләтнең әле бернигә бирешми торган затлы Асылгәрәй хәзрәтләре, чуен кебек нык Зимагур Тимербулатлары бар. Кара урман эчләрендә дә, кыя-тау араларында да, зур далаларда да алар барыбер кеше булып калалар, кешеләргә ярдәм итәргә юл табалар. Һәм дөнья барыбер менә шундый кешеләр җилкәсендә бара.

Ул арада Солтанхәким уянып эчәргә сорады...

Бала әле һаман ут булып яна, әмма ашагач аңа бераз хәл кереп киткән, ул сөйләшә ала иде. Әтисеннән теге Тимер бабай турында сорады, саташып ятса да, ул аның исемен дә, үзен дә хәтерләп калган икән. Алтынчы карт калдырган ризыклар белән тагы тамак ялгап куйдылар, учакны яңадан тергезеп җибәрделәр. Инде кич тә җитеп килә, төнгелек турында уйларга вакыт иде.

Кич җитте, кояш, тау сыртлары арасына кереп, юкка чыкты.

Асылгәрәй хәзрәт ахшам намазын укып йөргән арада, аркасына киндер капчыгын асып, Тимербулат карт та килеп җитте. Ул бер савыт белән кайнар тавык шулпасы китергән иде, икенчесенә бал белән чәй алган. Тирә-юньгә тәмле исләр таралды, Зәйтуганнан чыкканнан бирле мондый ризыкларны күрмәгән качаклар хәйран калдылар. Ике карт, ике яктан утырып, Солтанхәкимгә кашыклап тавык шулпасы ашаттылар, кәрәзле бал белән чәй эчерделәр, аннан авылдан килгән бишмәткә төреп яткырдылар. Авыру бала эреп йокыга киткәч, ике карт тагы сүзләрен дәвам итте.

— Әгәр теге заманнар булса, мин сине үзебезнең авылга мулла итеп кенә алып кайтыр идем, — дип сүз башлады Тимербулат карт. — Бездә хәзер мәеткә җеназа укучы да калмады, Коръәнне белүчеләрне барысын алып бетерделәр. Әм-

ма сине анда тотмаячаклар, алып китәчәкләр. Син аның өчен ул тәмугтан качмадың. Ә менә улыңны беразга яшереп торып булыр иде. Вакытлыча булса да, дим...

Шулай диде дә Тимербулат карт, туктап калды...

Аның бу дини татар кешесенә, аның авыру улына ярдәм итәсе килә иде. Монда ятсалар, аларны килеп тотачаклар, китсәләр — бала авыру, хәлсез. Аның белән Урал тауларына керергә ярамый, алар аны уза алмаячак. Ә ничек ярдәм итәргә бу Алла бәндәләренә? Малайны монда калдырып торырга кирәк. Терелгәнче ул Тимербулат картларда яшәп торыр, аннан күз күрер. Чөнки бүгенгесе кадерле, башның исән булуы кирәк. Тимербулат карт башка юл күрми.

— Сез монда озак ята алмассыз, — дип дәвам итте Тимербулат карт, хәзрәтнең дәшмәвен күреп. — Алар авыл буенча котырып йөри инде, бу тирәгә дә килеп чыгулары бар. Улың бу хәлдә юлга чыкса, озак бара алмас. Шуңа күрә әллә аны миндә генә калдырып торасыңмы, дим? Терелгәнчегә кадәр. Аннан күз күрер тагы. Бүгенгесе кадерле бит, туган, баш исәнлеге кирәк. Тикшереп йөрүчеләргә үз улым, диярмен, үз улым кебек карармын.

Асылгәрәй карт мондый көтелмәгән тәкъдимнән башта югалып калды...

Аның Солтанхәкимне кайдадыр калдырып китү уе башына да килмәгән иде. Монда, кара урманда, тау-таш арасында, беренче күргән кешегә. Юк, бу мөмкин хәл түгел. Ни күрсәләр дә, бергә күрерләр, аларга аерылырга ярамый.

— Рәхмәт, туган, мондый сүзеңә, — диде ул, Тимербулат картның күңелен китмичә генә. — Бара алсак, без бергә барырбыз инде. Сине дә гел тикшереп торалар, дисең бит. Мин дә ул юлда ялгызым нишләрмен?

— Үзеңне кызганып әйтүем, — диде Тимербулат карт. — Юл бик ерак һәм авыр бит. Бу таулардан таза-сау кеше дә үтә алмый, ә син авыру бала белән. Юлны белмисең, артыгыздан куа киләләр. Аптыраганнан, үзеңне җәлләп әйтүем иде, кордаш, дөрес әйтмәсәм, кичер.

Тимербулат карт бу төнгә авылына кайтып тормады. Яңа танышларын бу хәлдә, бу билгесезлектә ташлап китәргә күңеле бармады. Аска чыршы-карагай ботаклары җәеп, өскә карт алып килгән бишмәтне ябынып, Солтанхәкимне уртага алып, бергәләп йокларга яттылар. Солтанхәким төне буе ыңгырашып, саташып чыкты. Аның ике карт арасында яткан арык гәүдәсе ут булып яна, үзе туктаусыз калтырый, бизгәк тота иде. Таң алдыннан аны көзән җыера башлады, ул инде ашый-эчә алмый иде. Картлар, аңа карап, тирән хәсрәткә калдылар. Малайны юлга алып чыгып китү түгел, кузгатып та булмый иде...

Ул арада авыл ягыннан котырып этләр өргән, ат тоякла-

ры тупырдаган тавышлар ишетелде. Тавышлар туп-туры бу якка таба килә иде. Моны ишетеп, картлар тынсыз калды, бер таралып яткан балага, бер авыл ягына карадылар. Бер фикергә килергә кирәк иде...

— Син кач, — диде Тимербулат карт, кыска һәм кискен итеп. — Уңга китсәң, Белоретка барып чыгарсың, сулга китсәң — Баймакка. Әмма анда юллар булса да, тыныч түгел, тикшерү күп, тотарлар. Турыга барсаң, тоташ таулар, үтүе бик авыр булыр, әмма анда сине эзләүче булмас. Улың хәзергә миндә калып торсын, аның өчен борчылма, үз балам кебек карармын.

— Ә аларга нәрсә дип әйтерсең? — диде Асылгәрәй карт, тавыш килгән якка күрсәтеп.

— Үз улым, диярмен. Аугa чыккан иде, авырып китте, диярмен. Син минем өчен борчылма, мин мондыйны гына күргән. Ходай насыйп итсә, бер күрешербез. Безнең авылның исеме Үзәнбаш була, шуны онытма. Минем исемне инде беләсең...

Эт өргән тавышлар инде якында ук ишетелә башлады. Бу тавыштан Солтанхәкимнең озын керфекләре тетрәп куйды, ул, күзләрен зур итеп ачып, тирә-ягына карады. Аның өстенә ак сакаллы ике карт иелгән иде. Әмма Солтанхәким аларны танымады, аның тәне генә түгел, хәтере, җаны да ут булып яна иде. Ул ыңгырашып күзләрен йомды һәм аларны инде башка ачмады. Аңа хәзер ни булса да барыбер иде. Аның җаны, кырык сыртны бер мизгелдә үтеп, Зәйтуганга кайтырга кубарылган иде.

Асылгәрәй карт моның язмыш икәнлеген аңлады. Әйе, Солтанхәким монда калырга тиеш иде. Димәк, бу алтынчы картны алар янына Аллаһы Тәгалә үзе җибәргән.

— Хуш, бәхил бул, улым, — диде ул, Солтанхәкимнең ут булып янган битләреннән үбеп.

Картның кайнар яшьләре улының битләренә тамды, әмма малай уянмады, аңга килмәде. Ул әйтерсең лә инде мәңгелек йокыга киткән, бу дөнья белән мәңгегә бәхилләшкән иде...

Ата кеше улы янында дога кылды.

Тимербулат карт ул арада аңа юл өчен бөтен калган ризыкларны тутырды.

Артта этләрнең һау-һаулап өргәннәре, сакчыларның кычкырган тавышлары якынайганнан-якыная барды.

Алда исә стена булып кара кыялар басып тора иде.

Алда Урал тауларының кеше үтә алмаслык кырык сырты җәелеп ята.

Асылгәрәй карт аларны инде берьялгызы үтәргә тиеш иде...

Ул уңга да, сулга да борылмады, туп-туры китте...

Урал тауларына таба, язмышына каршы атлады...

* * *

Маһинур абыстай Уфага кадәр берничә көн кайтты. Бу поезд мал вагоннарыннан тормаса да, ул кеше белән шыплап тулган иде. Вокзалдагы теге чегәннәр дә, сукбайлар да, эшчесе-колхозчысы да — барысы да ничектер утыра алганнар, хәзер берсе өстендә берсе баралар.Тикшерә башлагач, яртысының билеты юк булып чыкты, китте тавыш, китте елаш, кем акча төртә, кем кызгандырып калмакчы була, берсенең дә поездден төшеп каласы килми.

Маһинур абыстайны халык төркеме бер почмакка китереп кысты, һәм ул шунда урнашып калды. Керүгә, ул карашы белән кызларын эзли башлады, әмма бу вагонда алар күренмәделәр. Ана аларны башка вагоннардадыр дип өметләнде, гел эзләп табып килеп керерләр дип көтте. Әмма балалары күренмәделәр.

Беренче төнне шулай, ничек кертеп төясәләр, шул рәвешле чыктылар, ә иртән вагон буйлап сакчылар китте. Алар һәр кешенең билетын һәм документларын җентекләп тикшерәләр иде. Мылтыклы сакчыларны күргәч, Маһинур абыстай коелып төште, зиһене таралып, мие томаланып китте. Алар билетсыз кешеләргә штраф салалар, ә документсызларны җыеп алып чыгып китәләр иде. Бигрәк тә ир-атларны һәм яшьрәкләрне җентекләп тикшерәләр, аларның очлы күзеннән беркем котыла алмый...

Менә алар Маһинур абыстай утырган почмакка да җиттеләр.

Биредә дә кайсының билеты, кайсының документы юк иде...

Маһинур абыстай кебек, биредә Магниткадан качканнар да бар икән, аларны, бала-чагалары белән акыртып, шунда ук икенче вагонга алып чыгып киттеләр, ә бер тукталышта исә сак астында поездден төшереп тә калдырдылар. Янында берничә кечкенә баласы булган бер татар хатынының документы бар, әмма билеты юк икән, аны штраф, дип кыса башладылар. Ә аның акчасы юк. Аларны төшереп калдырырга өстери башлагач, Маһинур абыстай, кызы Гайшәгә дигән билетны чыгарып, бу хатынга бирде. Башта аптырабрак торган хатын, шунда ук аңга килеп, үзенекен сукалый башлады:

— Бу безнең авыру әниебез, билетлар анда иде, мин русча аңлап бетермәдем, — дип акланырга тотынды.

Маһинур абыстайда, чыннан да, ике билет иде.

Аны шушы татар хатынының әнисе дип уйладылар, ахры, билетын тикшерделәр дә артык төпченеп тормадылар. Карчыкның кыяфәте дә авыру кешене хәтерләтә, шуңа күрә сакчылар аның белән артык мавыгып тормадылар, башкаларны тикшерә башладылар. Сакчылар китү белән, яшь хатын Ма-

һинур абыстайга рәхмәтләрен әйтә башлады, шул арада үзенең тарихын да сөйләп ташлады. Ул Чиләбедән Уфа тирәсендәге бер авылга кайтып бара икән, ире трактор заводы төзергә язылып килгән булган, котлован казыганда, җир басып үтергән. Бетле баракларда ничек кирәк алай кышны чыккач, хатын, балаларын алып, авылларына кайтырга булган, әмма аны вокзалда талаганнар, билетка дигән акчаларын алганнар. Мәрхәмәтле кешеләр аны поездга утыртып җибәргәннәр, әмма менә беренче тикшерүдә үк тотканнар. Әле ярый бу абыстай булган, аларны бер тиен акчасыз тау арасында төшеп калудан коткарган...

— Синдә ничек ике билет соң, абыстай? — дип сорап куйды ул, үзенекен сөйләп арыгач.

— Кызларыма дип алган идем, әмма алар белән аймыл булдык, — диде Маһинур абыстай, артыгын сөйлисе килмичә.

Чөнки монда да төрле кеше бар, аның качып кайтып баруын белмәүләре яхшы иде...

Маһинур абыстайның үзе белән сохаридан кала ризыгы юк иде, ул шуларны капкалап кайтты. Балалы татар хатыны исә кайдандыр ипиен дә, йомырка, бәрәңгесен дә тартып чыгарды, карчык алдына куйды. Аның бу абыстайны шул рәвешле булса да бәхилләтәсе, әҗерен бирәсе килде. Бу хакта әйткәч, Маһинур абыстай сабыр гына: «Аллаһ риза булсын, кызым», — дип әйтеп куйды. Бу яшь хатын «әниебез» дигәч, абыстайның да документларын тикшереп тормадылар бит, шулай булгач, ул да Маһинур абыстайга ярдәм иткән булып чыга. Шулай итеп, алар бер-берләреннән бәхилләр иде...

Ул арада томырылып Урал тауларына да килеп керделәр...

Килгән вакытта мал вагоныннан Маһинур абыстай аларны күрә алмаган иде, бер хикмәт икән ул Урал таулары. Әле кап-кара кыя-таулары каршыңа атылып килеп чыга, поездга ышкынып диярлек яныңнан йөгерә, әле берәм-берәм урманлы тау сыртлары тезелеп китә, сине бишек итеп тибрәтә. Урыны-урыны белән үзәнлекләр ачылып китә, анда авыллар, йортлар утырып кала, кешеләр чагылып үтә. Бу тауларның бер дә очы-кырые юк кебек, аларның кайчан да булса бетәсенә ышанып та булмый.

Шушы тау араларында аның төпчеге — Рәйсәсе ята бит...

Дога көтеп ята...

Карчык, кулларын күтәреп, озаклап дога кылды, бите буйлап күз яшьләре тәгәрәп төште...

Шушы тау араларында ире, улы Солтанхәким каңгырып йөриләр булыр. Инде исән-сау күрешергә насыйп итсен иде, аларны Аллаһы Тәгалә үзе сакласын. Кызлары белән дә Уфада күрешергә язсын, аларга бу явыз сакчылар кулыннан котылырга насыйп итсен. Инде барысы да Алла кулында, Ма-

һинур абыстай ире өчен дә, балалары өчен дә берни эшли алмый иде. Бары тик дога гына кыла ала...

Шулай бер-берләренең күңелләрен күреп, бер-берләрен юатып, Уфага да кайтып җиттеләр. Балалы хатын Маһинур абыстайны бик тә үз авылларына чакырса да, ул, рәхмәт әйтеп, баш тартты, чөнки аңа кызларының язмышын ачыкларга кирәк иде. Татар хатыны белән туганнар кебек кочаклашып аерылышкач, Маһинур абыстай Уфа вокзалында берьялгызы басып калды. Ул, могҗиза көткәндәй, күзләре белән кызларын эзләде. Әмма алар күренмәде. Маһинур абыстай вокзал эчләрен дә урап чыкты, урамда да эзләнеп йөрде, эскәмияләрдә дә озак кына утырып торды. Әмма кызлары күренмәде. Аптырагач, куркуын җиңеп, шул тирәдә сату итүче хатыннардан, хәтта кассирлардан да сорашып карады. Әмма апалы-сеңелле бу ике кызны бирედә беркем дә күрмәгән булып чыкты.

Маһинур абыстайның эченә курку төште. Әле ул һаман кызларын Уфада очратырмын, табармын дип уйлый иде.

Ә алар күренми. Ире Асылгәрәй хәзрәт тә кайтып җитә алмаган, ахры, ул да юк. Үзе Уфага хәтле чагыштырмача җайлы кайтып җиткәч, ул ире белән балалары да шулайрак кайтырлар дип уйлаган иде. Ә алар һаман күренми. Маһинур абыстайның күңелендә әле һаман өмет бетмәгән иде, «Бәлки, туп-туры Бөгелмәгә кайтып җиткәннәрдер», — дип уйлады ул. «Бәлки, башка юлдан киткәннәрдер», — дип, үзүзен юатырга тырышты. Алар бит Магниткада вакытта ук шулай килеште — кем ничек булдыра ала, шулай кайтырга ниятләделәр. Бәлки, инде алар, Аллаһ насыйп итеп, Зәйтүгангa ук кайтып җиткәннәрдер...

Алай да Маһинур абыстай әле тагы берничә төн вокзал каршындагы эскәмиядә кунды. Йә ире, йә балалары кайтып керерләр кебек тоелды аңа. Өченче көндә инде аның үзе белән сакчылар кызыксына башлагач, ул башын тагы диванага салды, әйберләрендә актарына башлады. Өстенә катлат иске-москы кигән бу сәер карчыкның кемлеген ачыклый алмагач, сакчылар, кул селтәп, читкә киттеләр. Маһинур абыстай исә монда артык калырга ярамаганлыгын аңлады, чөнки инде аның ашарына да юк, акчасы да бетеп килә иде. Ул, соңгы тиеннәрен җыеп, Бөгелмә поездына билет алды һәм туган якларына кайтып китте.

Ә биредә инде җәй уртасы иде...

Дөньяның иң матур, иң әкияти чагы...

Болыннарда билдән печән өлгергән, урман буйлары шау чәчәктә, кырларда иген күтәрелеп килә. Үзәнлекләрдә көтүкөтү маллар йөри, ачык урыннарда авыллар җәелеп ята. Дөньяда берни үзгәрмәгән, барысы да узган җәйдә Маһинур абыс-

тайлар илдән чыгып киткән хәлдә. Дөнья шаулап яшәп ята, тик анда Мәһинур абыстай белән Асылгәрәй хәзрәткә һәм аның балаларына гына урын юк...

Бөгелмәгә кайтып җиткәнче, Мәһинур абыстай тәрәзә яныннан китмәде...

Монда инде, Уралдагы кебек, документ тикшерүче мылтыклы сакчылар юк иде. Барысы да үзгә, барысы да җанга якын, кадерле. Җирнең, агачларның төсенә кадәр башка, туган якның исенә кадәр башка шул. Монда көне-төне дөпелдәп торган төзелеш шау-шуы да юк, атлаган саен таш-тимер дә өелеп ятмый, тирән чокыр-котлованнар да, завод торбалары да, домна мичләре дә, котсыз бараклар да, җир асты куышлары да юк. Монда кешеләр дә башка, бер җиргә ашыкмыйлар, кычкырышмыйлар, бер-берсен орышмыйлар. Үзләренчә, тыныч кына яшәп яталар.

Бөгелмәгә кайткач, ул туп-туры улы Равил белән килене Вәсимә яшәгән фатирга китте. Мәһинур абыстай аларның узган ел ук Ташкент якларына китүләрен белсә дә, бәлки, яңадан кайтканнардыр дигән өмет аны бирегә китерде. Әмма өмете юкка булып чыкты, ишекне таныш түгел марҗа ачты. Ул берни белми иде, каршында сәләмә киемле карчыкны күргәч, хәерче дип белеп, тизрәк ишекне ябып куярга ашыкты. Чөнки соңгы вакытта аларның исәбе-хисабы юк иде, әйтерсең бөтен шәһәр ачлар һәм хәерчеләр белән тулган...

Мәһинур абыстай ач иде, аның инде берничә көн берни ашаганы юк иде. Ачлыктан һәм хәлсезлектән аның башы әйләнде, зиһене томаланып китте. Бер йорттан сорап алып су эчте, капка төбендәге эскәмияләрендә хәл җыеп, утырып торды. Аңа хәзер ничек тә Зәйтуганга кайтып җитәргә кирәк иде. Ул шуның өчен мең чакрым юлга качып чыгып китте бит. Әле һаман ирен һәм балаларын шунда күрермен дип өметләнә, шул ук вакытта авылга һаман Шайтан Шакирлар хуҗа булуын да чамалый. Кайтып күренсә, аны тагы тотып кире җибәрүләре бар. Ул хәзер Асылгәрәй карт нәселеннән үлгәнче үч алачак инде. Ул булмаса, башкалары канны эчәчәк, чөнки бу власть өчен Асылгәрәй карт нәселе кара исемлеккә кертелгән, башлары сөрген сөрелгән һәм, алар уйлавынча, шунда череп бетәргә тиешләр иде...

Әмма, ни генә булса да, Мәһинур абыстай Зәйтуганга кайтмый кала алмый. Ул шуның өчен җәһәннәмнең үзеннән качып, юлга чыкты бит, иреннән, балаларыннан аерылды. Ачыкты, талчыкты, диванага сабышты. Аның хәзер бер телем ипи алырлык та акчасы калмады. Әле ярый аяк астында үлән бар, Мәһинур абыстай аны кайда күрсә, шунда өзеп каба. Әмма үлән ачлыкны басмый шул, бераз алдап торырга гына ярый.

Җитмәсә, кисеп-кисеп эче авырта башлады, тәне ут кебек янарга, кызышырга тотынды. Мәһинур карчыкка ничек кенә булса да Зәйтуганга, кызы Сабира янына кайтып егылырга кирәк иде. Аны әллә туган туфрак, әллә кабер туфрагы шулай алгысып үзенә тарта иде...

Ул, соңгы көчен җыеп, җәяүләп юлга чыкты...

Аның кеше күзенә чалынасы килмәде, битен каплабрак, олы юлдан читтә, ерак сукмаклардан барды. Чөнки мондагы тәртипләрне белеп бетереп булмый, авылыңа кайтып җитмәс борын ук тотып кире җибәрергә мөмкиннәр. Ул бит хәзер сөргенгә сөрелгәннәр исәбендә, хокуксыз, документсыз, йортҗирсез бер качак. Шуңа күрә кеше күзеннән читтәрәк булырга кирәк, кайтып җитәм дигәндә, харап итә күрмәсеннәр.

Агач араларында, яр буйларында туктап ял итә-итә, бик озак кайтты ул Зәйтуганга...

Бу тирәләрдәге һәр сукмакны, һәр калкулыкны, һәр куаклыкны яхшы белә Мәһинур абыстай. Теге елларда ире белән ат җигеп Бөгелмәгә еш бара иде алар. Базарга да, таныш-белешләргә кунакка да. Ул кешеләрнең күбесе биредә юк инде, кайсын сөреп, кайсын үтереп бетерделәр... Асылгәрәй мулланы бу тирәдә яхшы беләләр, хөрмәт итәләр иде. Зур укымышлы булганы өчен дә, тәртипле, яхшы кеше булуы өчен дә, дөнья рәте белгәне өчен дә. Кышларын күн белән тышланган кошовкаларга утырып, җәйләрен сиртмәле тарантасларда җил кебек очып кына үтә иде алар Әлмәт белән Бөгелмә арасын. Дөнья күрсеннәр дип, балаларны да үзләре белән алалар иде, алар өчен Бөгелмәгә барып кайту зур вакыйга була торган иде.

Менә хәзер Мәһинур абыстай, Зәйтуган мулласының абыстае, Колшәриф мулласының кадерле кызы, шушы юлдан кача-поса җәяүләп кайтып килә. Ни өчен шушы хәлгә калдырылды ул? Мулла хатыны булганы өченме, хәлле тормышта яшәгәннәре өченме, укымышлы булулары өченме? Алар бит авылда бер кешегә дә зыян китермәделәр, киресенчә, халыкны гел аклыкка, мәгърифәткә өндәделәр, аларга дин өйрәттеләр, тормыш алып баруда яхшы үрнәк булдылар. Һәм таланып, бернисез калдырылып, авылдан сөрелделәр. Ул хәзер үзен танып алып, яңадан сөргенгә тотып җибәрүләреннән курка. Юкка курка, чөнки аны инде беркем дә танырлык түгел. Аның тулы, түгәрәк гәүдәсе коры сөяккә калган, яңаклары суырылып, шәлперәеп килгән, эчкә баткан күзләрендә бер дә бетмәс хәсрәт һәм газап. Өстендәге киемнәре теткәләнеп, ертылып беткән, башындагы ак яулыгы көрән төскә кергән, чабатасы тузып төшеп калган, Зәйтуганга ул хәзер яланаяк кайтып килә...

Әмма нинди хәлдә булса да барыбер кайта...

Аның инде Зәйтуганга, бәлки, мәңгелеккә кайтып баруыдыр...

Маһинур абыстайның соңгы вакытта Аллаһтан бөтен сораганы — Зәйтуган туфрагында җирләнү иде. Ул Магниткаһың ач далаларында ятып калудан, күмелмичә, җир өстендә аунап ятудан яки кяферләр белән уртак чокырга тыгып куелудан коты чыгып курка иде. Ул нигәдер соңгы вакытта гел үлем турында уйлый башлады һәм җаны-тәне белән Зәйтуганга ыргылды. Күрәчәге каршына ашкынды. Ул бик арыган иде. Сөргендә бер ел күргәннәре аның бөтен бәхетле гомерен изеп-сытып, таптап киткән иде. Ул бу хәлдә үзенә дә, балаларына да ярдәм итә алмавын аңлады. Шуңа күрә Аллаһтан Зәйтуганга кайтаруын сорап ялварды.

Хәлсез аяклары белән лыштырдап кайта торгач, төн җитте...

Зәйтуганга хәтле әле шактый ара бар иде...

Маһинур абыстайның үлеп ашыйсы килде, әмма аның инде үлән ашарлык та хәле юк иде. Аны капкач, эченең кисеп авыртуы тагы да арта төшә, ашаганнан ашамавың хәерле. Шуңа күрә ул, кайда очраса, шунда иелеп, чишмә суы эчте, бит-кулларын юып, бераз хәл алды. Әмма юл өстендәге авылларга кереп, ашарга сорарга курыкты да, оялды да Маһинур абыстай. Тотып алып, кире җибәрерләр дип курыкты, танып алырлар дип тә оялды. Поездда кешеләрнең сөйләве буенча, быел халык үзе дә ач, авыллардагы хәлле кешеләр куып бетерелгәч, колхоз дигәннәре эшләп китә алмаган икән. Узган ел бөтен игеннәрне кычкыртып талап җыеп алып чыгып киткәннәр, яшергән кешеләрне атканнар, төрмәләргә япканнар. Хәзер исә икмәк тә юк, эшләргә кеше дә юк, рәт тә беткән икән. Ә рәт белгән кешеләр тегендә чери, төрмәләрдә, кабердә ята...

Маһинур абыстай Зәй буендагы бер чокырда бөгәрләнеп төн чыкты...

Инде аның ашыйсы да килми иде, бары тик кайда да булса баш төртәсе, авасы гына килә. Шушы бер ел эчендә ул инде мондый хәлләрне күп күрде, моннан авырракларын да кичерде, монысына гына түзәр, шәт, иншаллаһ... Бер төнгә түзәрлек кенә хәле бар әле аның. Чөнки төннең теге ягында — туган туфрак. Төннән ары — Зәйтуган, кызы Сабира, оныклары... Бәлки әле, ире Асылгәрәй хәзрәт, балалары Солтанхәким, Гайшәбикә, Мәрзиясе дә кайтып җиткәндер. Менә шул уй Маһинур абыстайга көч-куәт бирә, ач килеш өстерәлеп булса да Зәйтуганга кайтырга ярдәм итә. Һәм ул анда барыбер кайтып җитәчәк, Алла боерса.

Маһинур абыстай, таң белән торып, Зәй суында бит-күзләрен юды...

Аннан кыйбла якка карап, иртәнге намазын укыды...

Бу аның туган туфракта беренче намазы иде. Һәм шушы догалары аны авылына хәтле алып кайтып җиткерәчәк иде...

Менә олы юлдан шактый читтә таралып яткан Зәйтуган да күренде. Юк, башта каршыга ашыгып Очлытау килеп чыкты, аннан берәм-берәм Беләүлетау, Алыптау күренде, иртәнге томан арасыннан башкалары калкып чыкты. Маһинур карчык аларга йотылып, күзләрен ала алмый карап торды. Әйтерсең лә бу манзараны күзләренә генә түгел, йөрәгенә, һәр күзәнәгенә дә сыйдырырга, тутырырга тырышты ул. Үлем вагоннарында, кипкән далаларда, бозлы баракларда тилмереп ятканда, хыялында күпме күрде ул бу газиз күренешне. Чуклы талларга уралган Зәй суы, су буйларын каплап киткән куе әрәмәләр, авылга хәтле килеп җиткән яшел урманнар, Зәйтуганны бөтен яктан чорнап алган биек таулар, шул таулардан шаулап агып чыккан саф чишмәләр. Үзе Магниткада, таш-тимер арасында булса да, җаны менә шушында, Зәйтуган авылында булды Маһинур абыстайның. Ул шушы хыял, шушы күренешләр белән генә яшәде, шулар аны алып та калды, алып та кайтты...

Зәйтуганга килен булып төшкәч, ире Асылгәрәй аларның барысын да аңа күрсәтеп йөргән иде. Бу кадәр дә кыргый матурлыкны, бу кадәр дә табигый байлыкны аның бер җирдә дә күргәне юк иде. Аннан шушы гүзәллек эчендә аларның тугыз балалары тәгәрәп үсте. Алар Зәйтуганның иң татлы суларын эчеп, урман-әрәмәләреннән иң татлы җимешләрен ашап, тауларының иң саф һавасын сулап, бик кадерле, бик газиз балалар булдылар. Хәзер кайсы Урал тауларында, кайсы Җаек суларында, кайсы кая ятып калдылар... Калганнарының кайда икәнлекләре дә билгесез...

Маһинур абыстай авылга Зәй елгасы буйлап кичке якта кайтып керергә булды. Чөнки көндез күренеп йөрсәң, танып алулары бар, Шайтан Шакирга, советларга барып әләкләүләре мөмкин. Шуңа күрә аңа хәзер күзгә-башка күренеп йөрергә ярамый, авылга да карак кебек качып кына керергә кала...

Караңгы төшкәч, Зәйнең үзе белгән сайгак кичүеннән ул аргы якка чыкты. Аннан, куе куаклар арасыннан иелә-бөгелә, Сабираларның бакча башларына таба китте. Аның йөрәге читлегеннән чыгарлык булып дөпелдәп тибә, бөтен тәне бизгәк тоткан кебек калтырый, сызлый, яна иде. Ул Алладан кызының бусагасына кайтып егылырлык көч һәм сабырлык сорады. Чөнки бирәдә, бакча башында егылып калса, ул инде яңадан тора алырлык хәлдә түгел иде. Кызына кул сузымы җир калгач, ул бәрәңге бакчасына ятып җан бирергә мөмкин иде...

Маһинур абыстай кичке караңгыда абына-сөртенә Сабираларның мал абзарына хәтле барып җитә алды. Эчтән чыжылдатып сыер сауган тавыш ишетелә иде. Җылы сөт исе карчыкның борынына килеп бәрелде һәм ул, аумас өчен, абзар ишегенә сөялде. Һәм тәненнән, җаныннан соңгы көче китә башлады, бугазыннан хырылдаган аваз бәреп чыкты... Аяклары тотмыйча, карчык җиргә чүкте, кипшенгән телен чакка әйләндереп, «кызым...» дип кенә пышылдый алды.

Ике якта да кинәт кенә тынлык урнашты...

Сөт сауган тавыш туктап калды, эчтә Сабираның кузгалганы ишетелде...

Ана исә, хәлсезләнеп, җиргә сыгылып төште...

Хәзер инде аварга да була иде...

Ул Зәйтуганга, кызы янына кайтып җиткән иде...

* * *

Гайшәне, кулларын бәйләп, Магнитка төрмәсенә китереп ташладылар...

Бу Чиләбе өлкәсендә иң зур һәм иң рәхимсез төрмәләрнең берсе иде...

Буш далада шәһәр һәм тимер гиганты белән бергә аның төрмәләре дә үсеп чыкты. Төзелеш һәм төрмә бер-берләреннән аерылгысыз иде, берсе булмаса, икенчесе дә булмас иде. Чөнки бөтен Магнитканы төрмә тоткыннары һәм сөргенгә сөрелгәннәр төзи. Шушы бөек төзелеш хакына далада яңа төрмәләр салына, аларны дистә меңләгән тоткыннар белән тутыралар. Бу тоткыннарны бөтен ил буенча җыялар, бигрәк тә авылларга, бигрәк тә татар халкына каныгалар. Татар халкына карата илдән куылу, депортация инде 1930 елда ук, Магниткага нигез салган көннән башлана... Магнитка төрмәләре һәм сөргене аша кимендә йөз мең татар үтә, аларның яртысыннан күбесе шунда ачлыктан һәм газаптан үлеп кала...

Асылгәрәй картның егерме яшьлек су сөлегедәй сылу кызы Гайшәбикәне дә, сөргеннән качып барганда тотып алып, ач һәм ярым ялангач хәлдә Магнитка төрмәсенә китереп ташлаганнар иде...

Бу биек коймалары чәнечкеле тимерчыбыклар белән уратып алынган иксез-чиксез казармалар кирмәне иде. Бирегә инде кулакларны һәм качакларны гына түгел, азу ярган җинаятьчеләрне дә, кеше үтерүчеләрне дә утырта башлаганнар иде. Соңгылары җитәкчелек өчен сәяси тоткыннарны куркытып, кулда тотып тору өчен кирәк иде. 1932 елның ике аенда гына да, булганнарына өстәп, бу тоткыннар өчен тагы алтмыш барак төзелә, аларда егерме меңнән артык кеше тотыла. Тоткыннар арасында унсигез яшькә кадәрге үсмер бала-

лар да, алтмыштан узган чал картлар да була. Әмма иң күп халык — 20дән 50 яшькә кадәр, төрмә белешмәләрендә аларның саны ун мең дип күрсәтелгән. Адәм баласының иң көчле, иң сәламәт, нәсел калдыра, балалар үстерә торган чагы. Һәм ул бу алтын вакытын, илгә бөек төзелеш кирәк булганы өчен, төрмәдә уздырырга тиеш. Магнитка төрмәсендә иң күп утыручылар кулаклар һәм хәлле кешеләр була, ягъни татарлар. Күп кеше туган якларыннан ук хөкем карары белән туп-туры төрмәгә озатылган, ә гаиләсе бирегә сөргенгә сөрелгән. Кайберләрен качкан өчен тотып бирегә утырткан-нар. Дөресен әйткәндә, рәсми кәгазьләрдә бу урын «төрмә» дип түгел, ә «хезмәт белән төзәтү колониясе» дип атала. Һәм «төзәтү срогы» — өч айдан биш елга кадәр, ягъни кешесенә һәм гамәленә карап. Әмма күп кеше, биредәге эш һәм тормыш шартларына түзә алмыйча, шушында ук үлеп кала. Әйтик, рәсми мәгълүматлардан күренгәнчә, 1932 елгы тиф үләте генә дә Магнитка төрмәсендә һәр айны өчәр йөз кешене кырып сала, кайбер айларда бу сан хәтта мең ярымга җитә. Әле бу санаганнары гына. Санамаган, исәпкә алмаган мәетләр күпме — монысын беркем белми...

Гайшәне, куллары бәйләнгән хәлдә, менә шушы үләт базына китереп ыргыттылар...

Биредәге баракларда хәл сөргеннекенә караганда да куркынычрак иде.

Сөргендәгеләр, гаилә-гаилә, район-район берләшеп, авырлыкларны бергә бүлешәләр иде, ә монда барысы буталган. Мулласы да, кеше үтерүчесе дә, үсмер бала да, үлеп ятучы карт-коры да. Такта баракларда кешеләр өстеннән күселәр чабышып йөри, йә алар тоткыннарны тотып ашыйлар, йә тоткыннар аларны юк итә. Ашарга юк, эчәргә юк. Әйе, иң авыры — төрмәдә эчәргә су юк. Мунча юк, ут юк, ашханә юк, дистә меңләгән тоткынга бер табиб юк. Такта бараклар кышын катып үләрлек суык, җәен тынчу, чөнки форточкалар юк, җир идән. Тоткыннарны һәр көн конвой белән эшкә куалар, ә эшкә барырга кием бирүче юк. Хәтта чабатага да зур кытлык, аны өләшкәндә, талаш-сугыш була.

Магниткада иң авыр урыннарда төрмә тоткыннары һәм сөргенгә сөрелгәннәр эшли...

Иң тирән баз-котлованнарны көрәк һәм кәйлә белән алар казый...

Иң озын нигез, траншеяларны алар сала...

Бетон дамбаларны алар төзи...

Мартен мичләрен болытларга хәтле алар күтәрә...

Һәм күбесе, шушы бөек төзелеш астында сытылып, завод асларында ятып кала...

Әйе, Магнитогорск шәһәре һәм металлургия комбинаты кеше сөякләре өстенә төзелгән...

Бу бөек төзелеш астына татар сөякләре түшәлгән...

Төрмә тоткыннары белән яһүди Гейнеман һәм урыс Громов җитәкчелек итәләр. Алар җитәкчелек иткәндә, Магнитка төрмәсе Кызыл байракка лаек була. Бу Кызыл байракны тоткыннарны хезмәт белән яхшы тәрбияләгән өчен һәм планны һәрвакыт арттырып үтәгән өчен бирәләр. Ә үлү планын беркем санап тормый, чөнки илдә кеше бетмәгән, төрмәләр чоры әле башланган гына була.

Гайшәгә менә шунда өч ай гомерен уздырырга кирәк иде. Башкаларның срогы белән чагыштырганда, бу әле иң азы, шуңа күрә Гайшә ничек тә түзәргә булды, чөнки теге якта аны сеңлесе Мәрзия көтеп тора иде. Ул аны үзләре элек яшәгән баракка кайтып урнашкандыр дип өметләнде, Аллаһтан сеңлесен ташламавын елый-елый сорады. Ә мәхбүсләрнең эчкерсез кылган догалары кабул була, алар белән Аллаһ арасында пәрдә юк.

Гайшә дә, башкалар кебек, һәр көнне сак астында эшкә барды, ачлы-туклы хәлдә төнлә сак астында төрмәгә кайтып егылды. Ул җәй бик эссе һәм коры килде, Магниткада тиф үләте котырды, ул биредәге халыкның яртысын кырып салды. Кышын мәетләр айлар буе күмелмичә ята алса да, эссе җәйдә бу мөмкин түгел иде, чөнки бөтен Магнитка үлем базына әйләнергә мөмкин иде. Моны күреп, төзелештән чит ил эшчеләре китә башлады, комсомолларның эзе калмады, чөнки баш кадерле иде. Ә эшләргә, план бирергә кирәк, инде беренче домна мичләре җибәрелгән, аларга көн саен руда кирәк, илгә чуен кирәк, металл кирәк. Һәм исән калган халыкны, бигрәк тә төрмә тоткыннарын, кайда яна — шунда ыргыталар, калган көчләрен, җелекләрен суыралар.

Төрмәдә тиф үләте башлангач, Гайшәне мәет җыярга куйдылар. Бу төзелештә эшләүдән дә авыррак һәм куркынычрак хезмәт иде. Бу күрәләтә үлемгә бару дигән сүз, чөнки йогышлы чир хәтта сулаган һава белән дә күчә иде. Һәм төрмә начальниклары бу эшкә күбрәк татарларны куялар иде. Шулай итеп, сөргеннәрдә дә үлмәгән, төрмәдә дә исән калган авыл татарлары шушы йогышлы чирдән чебен урынына кырыла башладылар.

Аларны җыярга исән татарларны җибәрәләр иде...

Гайшә үзен күрәләтә үлемгә җибәрүләрен белде, әмма ул баш тарта алмый иде, төрмә тоткынының әмерне үтәмәскә хакы юк. Шуңа күрә ул бөтен саклык чараларын күрергә тырышты. Авыз-борынын һәрвакыт яулык чите белән кап-

лап йөрде, кулларын туфрак белән булса да ышкып чистартты, өс-башын төтенләтеп торды. Теленнән догасы китмәде, күңелендә гел Алла булды. Мондый шартларда исән калуның башка юлы юк иде…

Эссе җәйге көннәрнең берсендә, бараклардан мәет җыеп йөргәндә, Гайшә алар арасында гаять таныш бер йөзне очратты. Сап-сары булып саргайган, шыр сөяккә калган бу егет Аллаһъяр бабайның оныгы Самат иде, алар баракта бергә яшәгәннәр иде. Гайшә аны ачык калган зур зәңгәр күзләреннән таныды, чөнки мондый тирән, моңлы күзләр бары тик аңарда гына иде. Саматны бу хәлдә күргәч, Гайшәнең тыны кысылды, күзләренә яшь бәреп чыкты. Саматлар да качканнар иде шул, димәк, алар да тотылганнар. Һәм менә монда үлемен тапкан…

Гайшә, эченнән генә бисмилласын әйтеп, мәетнең күзләрен йомдырды. Әмма егетнең күзләре яңадан ачылдылар…

Газап тулы ул күзләрдә Гайшә үзенең чагылышын күрде һәм авып китә язды. Егет әле үлеп бетмәгән иде… Гайшә тизрәк аның кулларын тотып карады — алар әле җылы иде, алардан әле җан чыгып бетмәгән иде.

Егет, могҗиза күргәндәй, Гайшәгә тагы мөлдерәп карады, аннан тагы күзләрен йомды, аһын җуйды…

Ул яшәү белән үлем арасыннан үтеп бара иде…

Ике арада татар кызы Гайшә басып тора иде…

Гайшә Саматны, мәетләр арасыннан аралап алып, баракның икенче башына илтеп салды. Йөгереп барып, аңа су алып килде, Саматның көйгән иреннәренә тидерде. Үзе туктаусыз эченнән генә белгән догаларын укыды, су өстенә «Аятел Көрси» укып өшкерде, тиз генә «Ясин»ның бер өлешен укыды. Тиф барагы булганга, бирегә сакчылар керергә курка, монда Гайшә үзе хуҗа иде.

Самат күзләрен ачты, Гайшә биргән суны йотлыгып эчте…

Аның карашында рәхмәт тә, ялвару да, ярату да бар иде…

Гайшә ул көнне үзенең өлеш ризыгын Саматка алып килеп ашатты, валчыклап бүлеп, ипиен егет авызына салды. Ул һәр көнне аның янына йөрде, һәр көнне нәрсә булса да ашарга табып килә иде. Самат күзгә күренеп тернәкләнде, язмыш тарафыннан сузылган мәрхәмәтле кулга ул чытырдатып ябышты. Алар барагында барысы да тифтан үлеп бетте, ә Самат калды. Аның янында хәзер изге фәрештәсе — Гайшә бар иде…

Тиздән Гайшәне, тырышлыгын һәм пөхтәлеген искә алып, тоткыннарга ашарга пешерергә куйдылар. Бу инде ач үлемнән котылу дигән сүз иде. Дөрес, аш дигәнең дә өшегән кәбестә шулпасы да сулы ботка. Әмма бер валчык ипигә тилмергән кешеләр өчен бу зур сый, исән калу билгесе иде. Гай-

шә тоткыннарга ризыкны мөмкин кадәр күбрәк салырга тырышты, ә Саматны исә гел аерым ашатты. Самат инде аякка баскан, башкалар белән котлован казырга йөри башлаган иде. Ул хәзер төрмәгә дә өенә кайткан кебек ашкынып кайта, чөнки анда якташы, коткаручысы Гайшә көтеп тора иде. Шушы шартларда да исән калу өчен, кеше булып калу өчен адәм баласына өмет һәм хыял да кирәк иде...

Һәм татар яшьләре төрмәдә бер-берсен табыштылар...

Бер җанга әйләнделәр...

Әмма бу хакта бер-берләренә тел тибрәтеп берни дә әйтмәделәр...

Саматны Гайшәгә караганда алданрак чыгардылар, беркөнне ул ашарга килмәде. Шунда гына Гайшә үзенең аңа ни дәрәҗәдә ияләнүен, аңа тартылуын, аны сагынуын аңлады. Зәңгәр күзле бу тыйнак егет караңгы төрмә тормышында аның бердәнбер яктылыгы булган икән. Һәм бу хакта берберләренә бер сүз әйтмичә, алар тагы аерылды. Гайшәнең төрмә срогы туларга әле шактый вакыт бар иде. Төрмәдән чыккач, Гайшә Саматны табамы-юкмы — анысы да билгеле түгел иде...

* * *

Мәрзия, елап, бародактан урамга чыгып йөгерде...

Бу ач далада, таш-тимер арасында аның беркеме дә калмаган иде...

Ул апасының: «Ни булса да, татарларны эзләп тап», — дигән сүзләрен исенә төшерде һәм елый-елый җир асты куышларын эзләп китте. Чөнки туганнары качкан өчен, күп татарларны бараклардан куып чыгарганнар, алар хәзер, җир астына куыш ясап кереп, шунда яшәп яталар иде. Әмма ничек тапсын аларны Мәрзия бу иксез-чиксез далада? Җитмәсә, көн дә кичкә авышып бара, каршыга әле ач этләр, әле сукбай-хәерчеләр килеп чыга. Мәрзиянең инде ашыйсы да килә, апасы биреп калдырган сохарилар инде әллә кайчан бетте, валчыгы да калмады. Аяк астындагы үләнне дә әллә кайчан ашап бетергәннәр, ичмасам, бөртеген дә калдырмаганнар. Мәрзиянең эсседән эчәсе дә килә башлады, әмма бу тәртипсез далакырда су да тапмады, сорарга урысча сүз белмәде...

Шулай йөзләгән бараклар арасында бәрелеп-сугылып йөргәннән соң, ул бистә читендәге бушлыкка килеп чыкты. Ул бик арыган иде, аның аз булса да ятып торасы килде. Аңа хәзер ашарга да, эчәргә дә кирәкми, боларның барысыннан да котылырга, кантарлар арасына кереп, бөгәрләнеп ятарга кирәк иде. Аның тизрәк бу газаплардан котыласы, озак-озакка йокыга китәсе килде. Һәм ул кызыл балчык өемнәре арасы-

на кереп ауды. Аның инде уянасы килми иде. Чөнки монда аның инде беркеме дә юк бит. Гыйлемгәрәй абыйсын күз алдында атып үтерделәр, Гайшә апасын, кулларын богаулап, төрмәгә алып киттеләр, әти-әнисе һәм Солтанхәким юкка чыктылар. Аларның инде баракта да урыннары юк, анда исерек урыслар йоклап ята. Мәрзияне беркем белми, Мәрзия үзе дә инде беркемне танымый, белми...

Шул хәсрәтле уйлар белән ул күзләрен йомды. Һәм шунда ук аңа рәхәт, бик рәхәт булып китте...

Дөнья аллы-гөлле нурлар белән тулган, тирә-якта чишмәләр шаулап, кошлар сайрап тора. Һәм шушы матурлык арасында Мәрзия йөгереп йөри. Тукта, бу аларның Зәйтугандагы өйләре түгелме соң? Әнә бит, бакча башыннан гына Зәй елгасы агып ята, анда зур-зур таллар үсеп утыра. Мәрзия белән Рәйсә шул таллардан Зәй суына сикерәләр, аннан балыкка әйләнеп, йөзеп китәләр. Аннан кошка әйләнеп, һавага очалар, Зәйтуган өстендә бөтерелеп әйләнәләр. Аннан ике арага биек-биек таулар чыгып баса. Бу Урал таулары икән, алар Рәйсә белән шуның арасында очып йөриләр икән. Һәм кавыша алмыйлар, таулар аларны гел аера, гел араларына кереп баса. Мәрзия, елап, бу хакта әйтергә Зәйтуганга очып кайтып китә. Аларның өйләре каршына тупырдап торган ак ат килеп туктаганын күрә, тарантаста әтисе белән әнисе парлашып утырганнар. Мәрзия дә алар янына килә, алар белән китмәкче була. «Сиңа әле иртәрәк, кызым», — дип, әтисе аны күтәреп ала һәм өйгә алып кереп китә. Ак ат, әнисенең берүзен алып, томырылып чабып китә. Менә ул авыл өстендә җирдән аерыла, ак болытлар арасыннан очып бара да, Мәрзиянең әнисен алып, күздән югала... Мәрзия әтисе кулында ятып кала... Ул аңа һаман: «Сиңа әле иртәрәк, кызым», — ди. Менә ул аны өйгә алып кереп сала. Юк, бу аларның Зәйтугандагы өйләре түгел бит, бу әллә нинди караңгы урын. Бу бабай да аның әтисе түгел, бөтенләй башка карт бит. Мәрзия аны караңгыда таный да, танымый да. Әмма тавышы бик-бик таныш... Тукта, ул аны баракта күргән иде бит, ул алар белән бергә яши иде, гел Коръән укып утыра торган бабай иде.

Мәрзия күзләрен киереп ачты һәм караңгыда таныш йөзне шәйләде...

Әйе, ул аны таныды, бу бит — Аллаһъяр бабай! Әмма кайда соң ул, һаман төштә түгелдер бит инде? Алай дисәң, әтисе кайда, Зәйтугандагы өйләре кайда? Бу бит җир асты куышы... Әнә каршыда чытыр-чытыр чыра яна, идән уртасындагы учакта нидер пешә. Караңгыга күзләре ияләнә төшкәч, Мәрзия җир астында үзе кебек балаларны да күрде, болар Аллаһъяр бабайның оныклары иде. Димәк, Мәрзия хәзер алар арасында! Димәк, бу төш түгел, һәм аңа: «Сиңа әле

иртәрәк, кызым», — диюче карт аның әтисе түгел, ә Аллаһъяр бабай!

Әйе, бистә читендәге кызыл балчык өеме арасында үлеп барган Мәрзияне Аллаһъяр карт табып алган иде. Аның улы белән килене ачтан үлгән, оныгы Самат качкан өчен, аларның барысын да барактан куып чыгарганнар иде. Җир казып керү өчен дә махсус рөхсәт кирәк, алар да хисапта. Бу землянкаларның берничә гаилә өчен зурлары да, аерым гаилә өчен менә шундый кечкенәләре дә бар. Аллаһъяр карт оныклары белән кечкенә генә җир куышында яшәп ята иде. Шулар янына даладан ул кечкенә Мәрзияне дә күтәреп кайтты. Чөнки монда ятып калса, бу баланың бүген төнлә үк үләчәген ул яхшы белә иде. Ач этләр, дала шакаллары, явыз бәндәләр мондый корбанны эзләп кенә йөриләр.

Шулай итеп, Мәрзия җир астында яшәп калды...

Бу аның ач үлемнән котылуы иде, аның өчен кылынган изге догаларның нәтиҗәсе иде.

Мәрзия үзенең яңа йортын ныклабрак карады. Бу капкараңгы баз кебек бер урын иде. Аның стеналары чыбык-чабык, салам катнаштырып, балчык белән сыланган, түбәсенә кәс ябылган, җир идәнле. Ишегеннән керү өчен, башта чокырга төшәргә кирәк, аннан соң гына җир базына үтәсең. Баштарак бу баз Мәрзиягә бик шомлы, куркыныч урын булып тоелды, чөнки анда һәрвакыт диярлек караңгы иде. Әмма тора-бара, караңгыга күзләре ияләшкәч, Мәрзия монда үзенә күрә бер тәртип барлыгын күрде. Баз уртасында түгәрәк тимер мич тора, аның торбасы түшәмнән урамга чыга. Шул мичтә ашарга әзерлиләр, чәй кайнаталар, киемнәрен киптерәләр. Базның чит-читләрендә ятак урыннары, сәкеләр тезелгән, аларга урын-җир, чүпрәк-чапрак җәелгән. Аллаһъяр бабайның урыны аерымрак, чәчәкле чаршау артында. Ул шунда намаз укый, яшереп кенә оныкларына дин өйрәтә, килгән-киткәнгә киңәшен бирә, өшкерә, үзенчә дәвалый...

Төрмәдә утырган оныгы Саматтан кала, оныклары барысы да кызлар, шуңа күрә җир куышын ялт иттереп, гел җыештырып, тәртиптә тоталар. Монда беркем беркемгә кычкырмый, ормый-сукмый, читкә какмый. Мәрзиянең күңеле күптән мондый тынычлыкка сусаган иде инде, йөзләгән кеше яшәгән барак аңа дөньяда иң ямьсез, иң куркыныч урын булып тоела башлаган иде. Тора-бара җир астында яшәү Мәрзиягә бик ошый башлады, чөнки монда башкалардан аерым тормыш иде. Әмма барысының да теңкәсенә ачлык тия, чөнки алар арасында бары тик ундүрт яшьлек Маһия генә эшли, паек ала иде. Ул үзе дә ашамыйча күтәреп кайткан ипи кисәге кемгә генә җитсен? Аллаһъяр бабай белән алар үзләре дүрт җан, бишенчегә Мәрзия килеп өстәлде. Аны та-

мактан аермасалар да, Мәрзиягә алар өлешенә керү уңайсыз. Шуңа күрә көндезләрен ул, азык эзләп, бистә белән дала арасында йөри башлады. Ул хәер сорашырга ояла иде, хәер, монда сорасаң да бирүче юк, барысы да үзләре ач иде. Мәрзия кайда үлән җыя, кайда эшләшеп берәр нәрсә ала, шулай азык эзләп көне үтә. Нәрсә генә тапса да, ул аны, авызына да капмыйча, җир базына алып кайта, уртак табынга куя. Шулай итеп, өйгә ни дә булса алып кайтуына куана, үзен инде шушы гаиләнең әгъзасы итеп хис итә...

Беркөнне шулай дала буйлап яшел үлән эзләп йөргәндә, Мәрзия бер мәеткә тап булды. Алар далада шактый очрый иде, чөнки аларны җыючы да, күмүче дә юк... Бу олы яшьләрдәге хатын-кыз иде, аның ак чәчләре кызыл балчык белән буталган, ә ачык калган зур зәңгәр күзләрен кара каргалар чукый. Бу хәл Мәрзияне бик нык тетрәндерде, ул бар көченә каргаларны куа башлады. Каргалар теләр-теләмәс кенә күтәрелделәр дә бер читкә барып кундылар, кызның киткәнен көтә башладылар. Ул китүгә, алар тагы мәет өстенә ябырылачаклар иде. Моны аңлап, Мәрзия хатынның түшендәге алъяпкычы белән йөзен каплап куйды, хәзер каргалар аның күзләрен чукый алмаячак иде.

Шулчак ул үзенең артында кемнеңдер басып торганын сизде һәм куркып борылып карады. Аның янында олы яшьләрдәге бер казах карты басып тора иде.

— Ул үлгән бит инде, нигә каплыйсың аны? — дип сорады ул, таягы белән мәеткә төртеп күрсәтеп.

— Барыбер кеше бит ул, — диде кыз, җитди итеп. — Болай ятмасын...

Казах карты аңа озак кына сынап карап торды...

Аның күптән бу тирәдә андый җавап ишеткәне юк иде. Биредә кешеләр хайваннан да түбән дәрәҗәгә төшеп баралар, кайберләре хәтта ерткычка әйләнгән иде. Ул далада мәет битен каплап йөргән кыз баладан аның кемлеген, әти-әниләрен сораштыра башлады. Бала татар кызы булып чыкты, әтисе мулла икән, бирегә Урал аръягындагы авылдан сөрелгәннәр. Аның яхшы нәсел баласы икәнлеген казах карты үзе дә сизенгән иде инде, чөнки башкалар биредә мәетләрне талап йөриләр, битләрен каплап түгел. Әти-әнисенең, туганнарының юкка чыгуын белгәч, аның бу татар баласына ярдәм итәсе килде.

— Әнә анда безнең йорт, — диде ул, рәшә уйнап торган дала ягына төртеп күрсәтеп. — Әйдә, мин сиңа бераз ашарга бирим. Миһербанлы бала булырга охшагансың, мин дә сиңа ярдәм итим.

Бистәдән алай ерак китәргә курыкса да, ашау сүзе Мәрзияне магнит кебек үзенә тартты. Сөргендәгеләргә җирле

халык белән аралашырга, бистәдән ерак китәргә ярамый иде, әмма бу җәйдә барысы да тиф белән көрәшә, берсендә дә бала-чага кайгысы түгел. Моннан файдаланып, Мәрзия курка-курка гына казах карты артыннан ияреп китте. Монда, ачык далада, балаларның гына түгел, олы кешеләрнең дә юкка чыгуларын, үлеп калуларын еш сөйлиләр иде. Шуңа күрә кешеләр бистәдән ерак китмәскә тырышалар, ә ачлык барыбер шул якка куа...

Әмма казах картының киез тирмәсе алай ерак булып чыкмады, аның йорт дигәне дә берничә юрта икән. Алар янында каралып беткән балалар кайнаша, этләр чабулый, ерак та түгел маллар утлап йөри. Ә казанда... Ә казанда быкыр-быкыр килеп нидер пешә, аның исе бөтен далага таралган. Мондый тәмле исне Мәрзиянең Зәйтуганнан киткәннән бирле тойганы юк иде инде, бу яңа пешкән ит исе иде.

Казах карты аны үзләре белән табынга утыртты, алдына бер табак ит китереп куйды. Аның исеннән башлары әйләнсә дә, Мәрзия башта, рөхсәт сорап, кулларын юып килде, чөнки әти-әнисе аны шулай өйрәткән иде. Аннан, бисмилласын әйтеп, кечкенә генә бер кисәкне авызына китерде. Әмма каба алмады, күзләренә яшь бәреп чыкты. Ачтан интеккән әти-әнисен, туганнарын күз алдына китерде, җир базында бер телем ипигә тилмереп яткан Аллаһъяр бабайлар хәтеренә килде. Битләре буйлап тәгәрәгән яшьләре кулындагы ризыгына тамды.

Барысы да, ашамыйча, аңа карап торалар иде.

— Аша, кызым, аша, — диде казах хатыны, итле табакны аның алдына этеп. — Без, Аллага шөкер, көн дә ризыклы. Сезнең андагы хәлләрне сөйләп бетерә алмыйлар бит...

Иттән соң табынга шулпа килде, аннан бавырсак чыкты, аннан соң куе сөтле чәй бирделәр. Мәрзия барыбер артыгын ашый алмады, ел буе ач яшәгән балага берничә кисәк ризык та җитте. Бу ризыкларның бер өлешен бик тә Аллаһъяр бабайларга алып кайтасы килде, әмма ничек оялмыйча сорап аласың? Бу хәтле ашатканнарына да рәхмәт инде.

Ризыктан соң кыз кулларын күтәреп дога кылды, хуҗаларга рәхмәтләрен әйтте. Аны ата-анасы шулай өйрәткән иде...

— Аллаһ сезне киң нигъмәтле итсен, — диде ул, дога кылып бетергәч, олыларча җитди итеп.

Аңа кушылып казахлар да дога кылды...

Алар Аллага ышансалар да, дини гыйлемнәре юк, аның рәтен белмиләр иде. Ә бу ун яшьлек татар кызы догасын да белә, тәртибен дә белә, әдәп-әхлагы да бөтенләй башка. Ул сөргендә дә кеше булып кала алган, динен онытмаган, ә алар киң далада да Аллаһны онытып баралар. Әллә кайдан ки-

леп чыккан бу самими татар баласы аларның каткан күңелләрен йомшартып җибәрде, аның белән бергә йортка дога керде, нур керде...

— Син динне дә яхшы беләсең, ахры, кызым? — диде казах карты, аның дога кылуына ишарәләп.

— Мулла кызы бит мин, абый, — диде Мәрзия тыйнак кына. — Әти-әни безгә барысын да өйрәтте — намазын да, Коръәнне дә...

— Әллә Коръән дә укый беләсеңме? — диде казах карты, тәмам әсәрләнеп.

— Әйе, без барыбыз да беләбез. Әти яттан да белә. Олы абый-апалар да яттан белә иде. Әмма Магниткада моны белдерергә ярамый, күрсәләр, Коръәнне утка ягалар. Анда татарлар Коръәннәрен мендәр эчендә генә саклыйлар...

Моны ишетеп, казахларның күзләренә яшь килде...

Шулхәтле дини, укымышлы халыкны сөргендә черетүләрен алар аңлый алмадылар. Теге заманнарда казах далаларында дин таратып йөргән халык бит ул — татарлар. Бөтен казах-кыргызга дин шул яктан килә иде. Кышларын чана, җәйләрен кул арбасы тартып, аңа китап төяп, татар шәкертләре казах-кыргыз балаларына сабак укытып йөриләр иде. Алар хәзер барысы да әнә шул Магнит төрмәсендә чери инде. Бу илгә укымышлы кешеләр кирәк түгел шул, бу илгә мал көтүчеләр һәм тимер кайнатучылар гына кирәк...

— Балам, укы безгә дә бер-ике аять, йортка Коръән керсен, ичмасам, — диде казах карты, күз яшьләрен сөртеп. — Бездә дин бетеп бара инде, сезнекеләр дә йөрми хәзер, безнекеләргә дә кирәкми. Кая бара бу дөнья?

Мәрзия бу олы кешенең соравына кире җавап бирә алмады...

Казах хатыны белән бер читкә барып, тәһарәт алды, өс-башын тәртипкә китерде, яулыгын олылап бәйләде. Аннан әдәп белән генә өстәл артына барып утырды да, бисмилласын әйтеп, күңелдән Коръән укый башлады. Күп кыска сүрәләр белә иде ул, әмма башлап «Фатиха»ны укыйсы килде. Казах гаиләсе бу татар баласының шаулатып Коръән укуын тын алырга да кыймыйча, әсәрләнеп тыңладылар. Дала җиле бу моңлы аһәңне тирә-юньгә таратты, Урал тауларына алып китте, кырык сыртны үтеп, туган якларга хәтле кайтарып җиткерә алды. Сөргенгә сөрелгән татар баласының җан авазы булып туган якларга Коръән моңы кайтты.

«Фатиха» сүрәсеннән соң Мәрзия «Ихлас», «Нәс», «Кәүсәр» сүрәләрен укыды, «Аятел Көрси» һәм «Раббәнә» белән тәмамлады. Аннан, әти-әнисе кебек, шушы гаилә бәхете өчен дога кылды, аларга иминлек, балаларының бәхетен күрүләрен теләде, әрвахлар рухы өчен дә дога кылды. Бу кадәр дә

гыйлемне, бу кадәр дә дини тәртипне күреп, казах гаиләсе таң калды.

— Кызым, кал син бездә генә, безнең балаларга шушыларны өйрәтерсең, — диде казах карты, бер фикергә килеп. — Әрәм булып ятма анда. Без тиздән бу урыннан күчәбез, беркем эзләмәячәк тә, тапмаячаклар да.

Аның бу баланы һич кенә дә ул төрмәгә кире җибәрәсе килми иде. Ул аны үзенең зур гаиләсенә кызлыкка ала ала, тора-бара берәр улының килене булыр. Йортка гыйлем, иман керер. Татарлар эшчән, тәртипле халык, бу якларда татарлардан кыз алу һәрвакыт зур дәрәҗә булды, андый гаиләләрдән зур кешеләр чыкты. Әгәр бу мулла кызы аларда калырга ризалык бирсә, йортка бәхет кенә китерәчәк...

— Рәхмәт, агай, яхшы сүзегезгә, — диде аңа каршы Мәрзия, олыларча җитди итеп. — Әмма мин сезнең белән китә алмыйм, чөнки мин әти-әниемне, туганнарымны көтәм. Мин ятим бала түгел бит, ата-аналы бала. Алла насыйп итсә, алар барыбер мине эзләп табачаклар, иншаллаһ. Әгәр рөхсәт итсәгез, сез моннан күчкәнче, мин монда килеп йөрермен, балаларыгызга булдыра алганча дин сабагы бирермен.

Казах карты монысына да сөенеп ризалашты.

Мәрзиягә ул үзе белән бер бөтен ипи бирде, капчыкка ит, бавырсак төреп тыкты. Тагы килергә чакырып, ярты юлга хәтле озата чыкты. Мәрзия җир базына очып диярлек кайтып керде, ачтан хәлсезләнеп яткан Аллаһъяр бабай алдына бер капчык ризык чыгарып салды. Ул картка барысын да түкми-чәчми сөйләп бирде, казах карты үзен бөтенләйгә чакыруын да әйтте, аларга Коръән укуын да сөйләде.

— Аллаһы Тәгалә яхшы бәндәләренә ярдәм итә шул, балам, — диде Аллаһъяр карт, кыз алып кайткан ризыкны тигез итеп бүлеп. — Синең иман нурың алар йөрәгенә юл ачкан. Бәхетле, бәрәкәтле бала булырсың, кызым, иншаллаһ! Китмичә дә дөрес эшләгәнсең, бу җирдә синең нәселең динне яңадан торгызачак әле, Алла теләсә...

Картның соңгы сүзләрен бик үк аңлап бетермәсә дә, Мәрзия бу гаиләгә ярдәм итә алуына чын күңелдән сөенде. Чөнки җир астында алар барысы да ач иде. Моннан соң ул казах тирмәсенә һәр көн барып йөри башлады, аларның балаларына дин сабагы бирүдән тыш, авыру казах хатынына өйләрен җыештырырга, керләрен юарга ярдәм итте, кирәк булганда малын да көтте. Кыз бер эштән дә куркып тормый, көче җиткәннең барысын да эшли, кул арасына керергә тырыша иде. Чөнки аны әти-әнисе эштән курыкмаска, кайда да эшләп ашарга өйрәткән иде. Чөнки ул, берни эшләмичә генә, килгән саен ризык күтәреп кайтып китәргә уңайсызлана иде. Ә ризыкны ул җир базына җәй буе ташыды.

Ә инде уку мәсьәләсенә килгәндә, казах балалары иман шарты һәм бер-ике дога ятлаудан ары китә алмадылар. Ата-ана монысына да җире-күге белән куанды, чөнки алар үлгәч, менә шулар белән булса да дога кылучылар кала иде. Алар, динне белеп бетермәсәләр дә, күңелләреннән барысы да Аллага ышаналар иде. Казах карты исә намаз тәртибен дә белә икән, теге елларда татар шәкертләреннән сабак алу аңа да эләккән, шуңа күрә ул татар телен дә шактый яхшы белә булып чыкты. Карт, вакытын табып, җомга көннәрендә булса да, Мәрзия белән бергә намаз укыды, алар артына авыру казах хатыны, балалары да килеп баса иде. Моңа бөтенесе дә чын күңелдән куаналар, чөнки казахлар шушы далалары кебек киң күңелле һәм эчкерсез халык иде. Һәм казах карты хәзер бөтен тирә-юньдә иң дини, иң укымышлы кеше булып исәпләнә иде...

Җәй ахырына таба казахлар тирмәләрен җыя башладылар...

Казах карты Мәрзиягә тагы бер тапкыр үзләре белән китәргә тәкъдим итеп карады, чөнки бу тәртипле, иманлы, эшчән баланы аның һич кенә дә бу таш төрмәдә калдырасы килми иде. Әмма Мәрзия әдәп белән генә тагы баш тартты. Чөнки ул ата-анасын, туганнарын көтә иде. Чөнки Аллаһъяр бабайның: «Синең нәселең монда динне яңадан торгызачак», — дигән сүзләре бар иде...

Казах гаиләсе татар кызы белән елап аерылышты. Аңа күп итеп өс-баш бирделәр, кышка җылы бәрән тунына хәтле тоттырдылар. Капчыгына дөнья хәтле ризык салып, казах карты аны үзе җир асты куышына хәтле кайтарып куйды. Алар Аллаһъяр карт белән озак гәпләшеп, сөйләшеп утырдылар, бергәләп намаз укыдылар. Мәрзиянең яхшы кешеләр кулында икәнлегенә тәмам ышангач кына, казах карты даласына кайтып китте. Икенче көнне исә алар, тирмәләрен җыеп, бала-чагаларын, мал-туарларын алып, Җаек буйлап аска төшеп киттеләр. Хәзер аларны иксез-чиксез далада эзләп таба торган түгел иде...

Мәрзия исә җир астында, үз милләттәшләре белән яшәп калды...

Ул әти-әнисен, туганнарын көтә иде...

Ул алар белән генә бәхетле була ала иде...

Шулай итеп, алар җәй буе ачлыкны белмәделәр.

Казах гаиләсе биргән ризыкны шактый озакка суздылар, икмәкне киптереп куеп, көзгә хәтле ашадылар. Әмма әкренләп ашарга бетә башлады. Ул арада тоташ яңгырлар, дала давыллары, ачы җилләр башланды. Җәй дисәң, җәй түгел, көз дисәң, әле аңа иртәрәк. Әмма җир астында инде салкынча, якмасаң, туңдыра башлый. Хәзер иң мөһиме — ягарга

күмер табу иде. Чөнки тирә-юньдә агачның заты да юк, күмерне җир асты куышларына бирмиләр, үзеңә эзләп табасы. Землянкаларда яшәүчеләргә бер генә юл кала — урлау. Ә аны бары тик тимер юлдан гына урларга мөмкин, тотсалар, йә төрмә, йә эт итеп кыйналу. Шуңа карамастан җир асты балалары барысы да күмер урларга йөри. Мәрзия дә Аллаһъяр картның оныклары белән, зур чиләк тотып, һәр көн тимер юлга күмер яки кокс урларга бара. Алар вагон бушатканны көтеп кенә торалар, аннан, каргалар кебек, чәчелгән күмергә ташланалар. Чиләк авыр, тезгә бәрелеп, күгәртеп бетерә. Көч-хәл белән җыеп алып кайткан бер чиләк бер ягуга җитә. Вагон килмәгән көнне күмерсез каласың, суыкта төн чыгасың.

Инде итәк тулы бала-чага белән кара көзгә керәбез дип кайгырып торганда, төрмәдән Самат кайтып керде.

Бу җир асты базы өчен иң шатлыклы көн булды.

Мәрзия аны башта караңгыда танымады, башкалар исә, тавышыннан ук танып, аңа ташландылар. Алар Саматны качкан, илгә кайткан дип уйлаганнар иде, ә ул төрмәдә утырган булып чыкты. Саматның кайтканына иң нык куанганы Аллаһъяр карт булды. Ул үзенең көннәре санаулы гына калып баруын белә иде, бу кыз балаларны кемгә калдырып китәрмен дип бик борчыла иде. Чөнки монда ир-атсыз гаиләне ач үлем, төрле мәсхәрә, җәбер көтә. Оныгы Самат менә шушы балалар хакына төрмәдән исән котылып кайткан иде.

Җир асты куышында Гайшәнең сеңлесе Мәрзияне күреп, Самат бик куанды. Ул, өйдәгеләрне җыеп, төрмәдәге хәлләр турында сөйләп бирде. «Ул мине үлемнән алып калды», — дип, Гайшә турында аеруча бер җылылык белән искә алды. Гайшә турында сөйләгәндә, аның тавышы калтырап китә, битләре алланып чыга иде. Элек бер баракта яшәгәнлектән, Аллаһъяр карт та Гайшәне яхшы хәтерли икән, чибәр, тыйнак бу кыз бала анда да күпләргә үрнәк иде. Саматның әйтүенчә, Гайшәнең дә төрмәдән чыгар вакыты җитеп килә икән.

— Син аны монда табып алып кайт, улым, — диде Аллаһъяр карт оныгына, үз исәбе белән. — Аны хәзер баракка кертмәсләр, каңгырып йөрмәсен, бергә торырбыз. Яхшы кешеләрнең балалары алар, әрәм булмасыннар...

Самат бабасының бу тәкъдименә бик теләп риза булды...

Ул Гайшәнең төрмәдән чыгуын тилмереп көтә башлады, һәр кич эштән соң элек үзләре яшәгән баракка барып, аны эзләде. Ул анда, төрмәдә, үлем һәм пычрак арасында, Гайшәгә иң кадерле сүзләрен әйтә алмады бит. Самат ул саф хисләрен үзе белән алып китте. Әмма ул аларны барыбер Гайшәгә әйтәчәк, белдерәчәк, иншаллаһ. Алар әле барыбер очрашачак. Чөнки бу хакта күкләрдә шулай дип язылган иде...

Гайшәнең тизрәк төрмәдән чыгуын татар егете Самат көтә...

Апасының тизрәк үз янына кайтуын кечкенә Мәрзия тилмереп көтә...

Сөргендә, җир асты куышында Гайшәне язмышы көтеп тора иде...

* * *

Этләр, һау-һаулап, алтынчы карт янына ыргылдылар. Алар артыннан, эзләренә бастырып, атка атланган сакчылар чаптырып килә иде. Алар туп-туры Тимербулат картка таба атладылар. Әмма карт аларга игътибар итмәде, саташып яткан Солтанхәким белән булашуын белде. Сакчылар, атларыннан төшеп, алтынчы картның документларын сорадылар. Бередә көненә кырык тапкыр тотып тикшергәнгә, картның авыл советы биргән мөһерле кәгазе һәрвакыт үзе белән йөри иде. Ул аны ашыкмый гына сакчыларга чыгарып бирде. Тегеләр инде үзләре үк картның шушы тирә кешесе икәнлеген чамалап алганнар иде, чөнки качаклар мондый яхшы өс-баш белән урманда йөрмиләр... Ә менә янындагы малае бик сәер күренә һәм шактый шикле. Аның өс-башы да берничә көн буе урманда бәргәләнеп йөргәнгә охшаган.

— Монысы кем? — дип сорадылар алар, камчы сабы белән малайга төртеп.

— Кем булсын, минем малай, — диде карт, бер дә исе китмәгәндәй. — Берничә көн элек үз белдеге белән аугa дип киткән иде, чак эзләп таптым менә. Әле ярый аю-бүре ботарлап ташламаган. Бизгәк ябышкан менә үзенә хәзер, әле тифмазар булмаса ярый. Ничек алып кайтып җиткерергә хәзер аны авылга, ат-мазар да юк, ичмасам.

Тиф, бизгәк сүзен ишетүгә, сакчылар тизрәк читкә киттеләр. Чөнки быел бу тирәдә барысын да тиф кыра, Магниткадан инде авылларга да үтеп керде. Шуңа күрә алар андый авырулар белән бик сак булырга тырышалар, урманда очрасалар, атып кына китәләр. Бу чирле малай белән дә шулай буласы иде, бәхете, янында кешесе булды...

Атлы сакчылар бу авыру малай белән маташмадылар, тизрәк китү ягын карадылар. Ул арада бераз туктап торган яңгыр тагы сибәли башлады, аннан коеп ук яварга тотынды. Этләр, чинашып, карагай ябалдашлары астына постылар, Тимербулат карт аларга кичтән калган сөякләрне ыргытты.Этләр, һаулашып, шуңа ябырылдылар, аларга инде качаклар да, сакчылар да кирәкми иде. Ә Тимербулат картка шул гына кирәк тә, чөнки ул бу этләрнең Асылгәрәй картның эзенә

төшүеннән курка иде. «Моннанераграк китсен Асылгәрәй кордаш, — дип уйлады ул, этләргә сөяк-санак ыргытып. — Бу палачлар куып җитәрлек булмасын. Иленә кайтсын, кешечә яшәсен, картлык көнендә тау-таш арасында бәргәләнеп йөрмәсен...»

Сакчылар, атларын борып, Магнитка ягына таба киттеләр...

Этләр, сөякләрен ташлап, алар артыннан чапты...

Тимербулат карт җиңел сулап куйды, ичмасам, хәзергә бу бәладән котылды. Соңыннан күз күрер тагы, хәзергесе кадерле. Хәзер бу баланы, авылга алып кайтып, аякка бастырырга кирәк. Ул бит аны атасыннан әманәт итеп алып калды. Инде авылга килеп тотып алсалар, үлеп яткан җиреннән урманнан таптым, дияр. Нигә теге көнне алдадың, дисәләр, урысчам шундый гына, аңлата алмаганмын, дияр. Башын җүләргә салыр, кирәк икән, сатып алыр. Хәзер заманы шундый, төртмичә яшәп булмый. Алдарга да туры килә, чөнки влач үзе шундый. Тимербулат карт гомер иткән кеше инде, рәтен белә. Юкка гына Зимагур Тимер, Зимагур Булат дип йөртмиләр аны бу якларда. Урманда ялгыз очрасалар, мондый палачларның бугазын тиз чәйнәп өзәр иде ул, әһ тә итә алмаслар иде. Ә бу баланы тоттырмаячак ул алар кулына, аякка бастырачак, Алла теләсә...

Тимербулат карт, үзе дә сизмәстән, Алланы искә төшерде...

Әллә Асылгәрәй картның ихлас динилеге тәэсир итте, әллә бу яхшы кешеләрне бик кызганды, аның аларга ярдәм итәсе килде. Бәлки, яңа властька карата ачуын шулай чыгарасы килгәндер, ачтан үлгән балалары өчен шул рәвешле режимнан үч алгандыр. Ни булса да, совет властена түгел, аның дошманнарына, качакларга ярдәм итәргә булды ул...

Хәзер Солтанхәкимне авылга алып кайтырга кирәк иде...

Агач ботакларыннан кап кебек нәрсә ясап, ул малайны шунда утыртты, аннан, иелеп, капны аркасына киде. Малай җиңел иде, сөяк тә тире генә, барлыгы да беленми. Әмма аның арык тәненнән шундый кайнарлык бәрә, хәтта картның аркасын пешерә башлады. Карт тирләп чыкты, әмма баруын дәвам итте. Атларга җайлы булсын өчен, ул кулына юан ботак алды, шуңа таянып, урман буйлап китте. Авылга әллә ни ерак түгел, ул урман артындагы борылышта үзән тутырып җәелеп ята иде...

Бу авылның исеме Үзән булып, бередән шул исемдәге елга башланып киткәнгә, мишәр гадәте белән авылны да Үзәнбаш дип йөртәләр. Ул ике биек тау арасындагы ачыклыкта урнашкан, аннан, тирә-яктагы урманны кисеп, тауларга кадәр җәелгән. Каршыдагы Керкәтаудан шаулап Үзән елгасы агып төшә, икенче яктагы Кагаташтан Кага елгасы башлана. Соңыннан алар икесе дә Агыйделгә барып кушылалар. Әм-

ма әле Агыйделгә җиткәнче, әллә ничә тау, әллә ничә үзән үтәләр. Агыйдел елгасына исә, Кама-Чулманына барып җитү өчен, Урал тауларының кырык сыртын үтәргә кирәк, шушы сынауны үтсә генә, ул зур Иделгә барып җитә ала.

Әллә һаман яңгыр сибәләп торганга, әллә инде көн кичкә авышып барганга, Тимербулат картның сәер биштәр асып урманнан кайтып килүен күрүче булмады кебек. Хәер, күрсәләр дә, аның бу гадәтләренә инде күнегеп беткәннәр иде. Бу Зимагур Булат урманнан аю күтәреп кайтса да гаҗәпләнмәсләр иде. Тик Тимербулат карт үзе дә бераз саклык чараларын күрде, башка вакыттагы кебек, урам уртасыннан җәелеп атламады, урман кырыйлатып, бакча башыннан гына кайтып керде...

Шабыр тир булып, баштанаяк чыланып өенә кайтып җиткәндә, көн инде кичкә авышкан иде. Карт башта авыру Солтанхәкимне сак кына урынга кертеп салды, малай тыныч кына йоклый иде. Моны күреп, карт тиз генә малларын карап керергә булды, алар, аны көтеп, капка төбенә өелешкәннәр иде инде. Ул кәҗә-сарыгын абзарга кертеп япты, тавык-чебешләрен кетәклеккә куып кертте, песиенә сөт салып эчерде. Аннан тиз генә, абзарга чыгып, кәҗәсен савып керде, Солтанхәкимгә җылы сөт эчертәсе килде. Карт белә иде — бу сөт аны аякка бастырачак, чөнки кәҗә сөте бөтен авыруларга да дәва, бигрәк тә үпкә чиренә. Умарта балы белән икесен берни алыштыра алмый, алар икесе дә картта бар, Аллага шөкер.

Әмма Солтанхәким, карт көткәнчә, тиз генә тернәкләнеп китә алмады...

Ул Магниткадан авыруның иң куркынычын — тиф чире ияртеп алып кайткан иде, ахры. Бу хакта карт беркемгә сиздермәде, беркемне өенә кертмәде, үзе дә чыгып йөрмәскә тырышты. Малайда тиф икәнлеген белсәләр, авылың-ниең белән яндырып китүләре дә бар. Шуңа күрә ул үзе белгән бөтен саклык чараларын кулланырга тырышты: өйне гел төрле үләннәр белән төтәтеп торды, барлык нәрсәне селте суы белән юды, Солтанхәкимнең бөтен өс-башын утка атты.

Карт күпме тырышса да, яман чир малайны ычкындырырга теләмәде. Ул инде Магниткада ук аның бугазына чытырдатып ябышкан иде, урманда исә бөтенләй аяктан екты. Кара бизгәк инде аның эченә төшкән иде, тәненә капкан утлы газап җелегеен суырды. Ул һаман саташты, һаман әтиәнисен, туганнарын чакырды. Айнып киткәндә, күзләрен ачып, сәерсенеп тирә-юньне күзәтте, озак кына Тимербулат картка карап торды. Аннан тагы аңын җуйды, тагы саташа башлады, сузып-сузып нindidер догалар укыды, тик алар безнеңчә түгел иде, Тимербулат карт аларны аңламады.

Кайвакытта карт үзе дә шомланып куя, малайның терелүенә өметен өзә башлый. Әмма шуңа карамастан ул аны кашыклап ашата, тавык шулпасыннан, чәчәк балыннан өзми, чәй урынына шифалы үлән төнәтмәләре генә эчерә. Җылы кәҗә сөтен исә ул Солтанхәкимгә көненә берничә тапкыр бирә иде. Бер эчкәндә, Солтанхәким, телен чак тибрәндереп, өшкереп бирергә кушты. Карт аптырап калды — ул өшкерү догаларын белми иде. Аңа малай алдында уңайсыз булып китте, бисмилласын әйтеп, ул сөтне Солтанхәкимгә сузды. Солтанхәким, яткан җиреннән генә пышылдап, нindидер дога укыды, сөт өстенә өшкерде һәм азлап-азлап эчеп куйды. Хәзер ул карт биргән һәр эчемлекне шулай өшкерә башлады, чөнки аның әти-әниләре дә шулай итә торганнар иде...

Әллә шушы өшкерүләрнең файдасы тиде, әллә Тимербулат картның тәрбиясе яхшы булды, Солтанхәким әкренләп терелә башлады. Моны күреп, картның сөенече эченә сыймады, ул Солтанхәкимгә урманнан тәмле җиләкләр, судан затлы балыклар тотып кайта башлады. Малай үзе дә әкренләп дөньяга чыга башлады, җәйнең җылысыннан рәхәтләнде, тәненә-җанына көч җыйды. Тимербулат картның сөйләве буенча, ул инде барысын да белә иде. Үзенең авырып урманда ятып калуын да, әтисенең аны Тимербулат картка тапшырып китүен дә белә иде Солтанхәким. Ул тимер кебек нык, әмма Солтанхәкимгә карата балавыз кебек йомшак бу бабайны ярата башлаган иде. Малай аңа чиксез рәхмәтле иде, чөнки аны үлем авызыннан шушы карт тартып чыгарды. Кеше шушы хәтле тәрбияне үз баласына да күрсәтә алмыйдыр, ә Тимербулат карт аннан да арттырды, Солтанхәким өчен елан сөте табарга да риза иде.

Бу көннәрдә малай белән мавыгып, карт сакчылар турында онытыбрак та җибәргән икән, ә алар әнә тагы авыл буенча иснәнеп йөриләр. Һәм бу юлы туп-туры Тимербулат картларга таба киләләр. Аларга авыл советы хатын да ияргән. Теге көнне урманда сакчыларны алдап җибәргән иде Тимербулат карт, бүген алар әнә авыл советын ияртеп киләләр. Бәлки, берәрсе күреп тишкәндер, бәлки, болай гына тикшереп йөриләрдер.

Менә алар, дөбер-шатыр килеп, өйгә дә килеп керделәр. Карашлары шунда ук түр сәкедә яткан Солтанхәкимгә төште...

Авыл советы хатын бер Солтанхәкимгә, бер Тимербулат картка карый, чөнки ул Зимагур Булатның холкын яхшы белә. Шул ук вакытта мылтык асып йөргән сакчылардан да курка, чөнки, качакларны яшергән өчен, барысына да төрмә...

— Кунак егет бар, дип әйтимме соң синдә, Тимербулат

әзи? — дип, авыл советы хатын татарчалатып кына эшне сиздереп куйды.

— Нинди кунак булсын ул, кыз-хатын, күрмисеңме, минем малай бит ул, — диде карт та, бер дә исе китмичә.

Аларның татарча сөйләшеп торулары сакчыларга ошамады.

— Что за каля-валя, говорите по-человечески! — дип үкереп җибәрде мылтыклы урыс. — Где документы?

Карт, кесәсендә шактый гына казынып, башта үзенең таушалып беткән мөһерле белешмәсен чыгарып күрсәтте. Аннан шкафтан 1920 елда туган улының метрикасын тартып чыгарып, сакчыларга бирде. Сакчы аны әйләндерде, тугландырды, бер документка, бер авырып яткан малайга карады.

— Бу Тураев Солтанморатмы? — диде ул, белешмәне авыл советы хатынның борынына төртеп.

— Әйе, әйе, — диде хатын, калтыр-колтыр килеп. — Сын малайка бар иде... Умирал калган иде... Дөресен кем белә инде аны...

Сакчылар авыл хатынының ни лепелдәвен аңламадылар, тегесе махсус шулай бутый иде. Чөнки ул Тимербулат картның менә ун ел инде ялгыз икәнлеген, бөтен балалары ачлык елны үлеп бетүен белә бит. Ә Зимагур карт, күзен дә йоммыйча, үлгән малаеның метрикасын әллә кайдан тартты да чыгарды. Бәйләнеп кара хәзер аның белән, бугазыңны чәйнәп өзәр ул мишәр...

Сакчылар ничек керсәләр, шулай чыгып киттеләр, аларга кәгазь генә булсын. Карт белән малай тагы үзләренчә яши башладылар. Тимербулат карт бу баланың үз улы булуына үзе дә ышана башлады кебек, һәрхәлдә, аның күңелендә шундый хисләр иде. Ачлык елны үлмәгән булса, аның төпчек улы Солтанморат та шушы яшендә булыр иде бит. Кара син, исемнәренә хәтле туры килеп тора бит — Солтанхәким, Солтанморат. Яшьләре дә бер. Кайсы яклары беләндер охшаганнар да кебек. Хәер, татар балалары кайда да бер төрлерәк инде алар...

Төпчек малае Солтанморатны хәтерләп тә бетерми инде хәзер Тимербулат карт. Ул Уфа төрмәсендә ятканда, малае туып кына калган иде бит. Тимербулат теге елларда аклар ягына да кушылмады, кызыллар артыннан да китмәде, урыс артыннан да бармады, башкорт артыннан да йөгермәде. Аның һәрвакыт һәрнәрсәгә үз фикере булды, шуңа күрәме ул һәр заманда агымга аркылы килде. Ул, башкалар кебек, авылда тирес арасында казынмады, гомер буе әле шахтада, әле чуен кою заводларында эшләде, әмма авыл белән дә арасын өзмәде. Аның төп нигезе, йорты, гаиләсе һәрвакыт Үзәнбашта булды. Тимербулат балаларын шәһәрнең бетле баракларына

алып китеп тилмертмәде, аларга завод сасысы иснәтмәде. Ул үзенә кирәкне һәрвакыт сатып алды, шәһәрдә эшләп, авылда бер дигән өй салдырды, мал-туары да балаларга ашарга җитәрлек иде. Бераз мая да туплап, инде барысы да ул дигәнчә булды, тынычлап картаерга да була дигәндә генә, шул инкыйлаб дигәннәре килеп чыкты да барысының астын өскә китерде...

Бер караганда, Тимербулат — эшче кеше, власть үзгәрүгә сөенергә генә тиеш иде, ә ул сөенмәде. Чөнки, аның уйлавынча, һәркем үз урынында булырга тиеш иде, эшче — станок артында, көтүче — мал-туар артында, крестьян — сука каласы артында, укыган кеше — язу өстәле артында, сәүдәгәр — кибет прилавкасы артында. Мулла — мөнбәрдә, ханнар — тәхеттә, гаскәр — хәзерлектә. Ә хәзер барысы да буталды, көтүчеләр тәхеткә менде, ханнар ләхеткә ятты, муллалар станок артына басты, эшчеләр кеше өйрәтеп йөри башладылар. Гаскәр бер-берсе белән сугыша башлады, әллә ниткән аклар, кызыллар барлыкка килде, тау аралары дип тормыйлар, авылга әле берсе, әле икенчесе бәреп керә. Әле сакаллы урыслар йөри мылтык күтәреп, әле чабаталы башкортлар йөри яңа дөнья даулап. Һәрберсе үзе белән өнди, җирдә җәннәт тормышлары вәгъдә итә. Ә мишәр Тимербулат берсенә дә кушылмады, ул үзе дә элеккеге эшче, аның авылда тыныч кына балаларын үстереп бетерәсе килә иде...

Әмма ирек бирмәделәр...

Егерменче еллар башында аны, аркасына мылтык терәп, авылдан алып чыгып киттеләр. Шул китүдән өч ел Уфа төрмәсендә ятты ул. Кайтып кергәч исә ачлык елны бөтен гаиләсенең үлеп бетүен белде. Бер алар гына түгел, авылның ярты халкы зиратка күчеп беткән иде. Авылны бер баштан — үләт чире, икенче баштан ачлык кырган, аңа хәтле бөтен ашлыкны, бөтен ризыкны кызыллар җыеп чыгып киткән булган...

Ул вакытта ук илленең теге ягында иде инде ул.

Бу хәбәрдән, бу кайгыдан ул кисәк кенә картаеп китте, бөтенләй үзенә бикләнде. Йөзен сакал-мыек басты, өен шайтан таягы каплап китте. Шулай шактый гомер аю кебек үз өнендә бикләнеп ятты ул. Аның өчен инде бөтенесе беткән иде — үзенә тугры хезмәт иткән яраткан хатыны да, тупырдап торган балалары да, гомер үзе дә. Мал-мөлкәтне дә әллә аклар, әллә кызыллар талап чыгып киткән, аңа кычыткан баскан җирдән һәм шактый беткән йорттан башка берни калмаган...

Әкренләп кабат дөньяга чыга башласа да, ул инде яңадан өйләнмәде, шушы ялгызлыгына күнекте. Хатын-кыз, авыл халкы аннан бераз шүрли дә иде, чөнки һәрвакыт кырыс бу карт кирәк вакытта усал да була белә, аны юкка гына Зима-

гур Булат дип йөртмиләр иде. Карт беркемнән бернәрсә сорамады, барысын да әкренләп үзе булдырды. Сарык-кәҗә тота башлады, үзенә җитәрлек тавык-чебеш, каз-үрдәк асрады, иптәшкә песи тотты. Урманга ауга йөрде, суда балык тотты, яшереп кенә алтын эзләде, алтын юдырды. Ул алтынның авылда нигә кирәк буласын Тимербулат карт үзе дә белми, әмма шул эш белән мавыгып китте. Асылгәрәй картлар очраганда, ул тау елгасында алтын юдырып йөри иде. Һәм бу очрашу аның бөтен тормышын үзгәртеп ташлады...

Картның тормышта максаты барлыкка килде, бала белән бергә өйгә җан керде, мәшәкать керде. Ул аңа, үзе дә сизмичә, Солтанморат дип эндәшә башлады. Карт аның йөзендә үзенең ачтан үлгән балаларының чалымнарын күрергә тырышты, Солтанхәкимне шуларның берсе итеп кабул итте...

Солтанхәким дә аңа тиз ияләште...

Авырып, саташып ятканда, күзләрен ачкан саен, ул каршында аның йөзен күрде, ул янында булгач, тынычланып тагы күзләрен йомды. Солтанхәким инде аңа ияләнде, ул аны үз тормышының бер өлеше итеп кабул итә башлады. Чөнки Солтанхәкимне караучы да, тәрбияләүче-ашатучы да, сакчылардан коткарып калучы да шушы карт иде. Шулай итеп, яшәү белән үлем арасындагы нәзек чик аша алтынчы карт малайның тормышына үтеп керде һәм шунда калды...

Солтанхәким шактый озак терелде, авырлык белән генә аягына басты. Әҗәлнең аны берничек тә ычкындырасы килмәде, ахры, әмма малайның гомере бетмәгән иде әле һәм ул Урал таулары арасында яшәп калды. Аның әле язмышына бу далаларда дөньяда тиңе булмаган мәчетләр салдыру, мәдрәсәләр тоту, динне торгызу, иманлы нәсел калдыру гамәлләре язылган иде. Әмма Солтанхәким хәзергә үзе болар хакында белми иде. Ул Тимербулат картның урман читендәге өендә үлем белән көрәшеп ята иде...

Инде җәй уртасы да үтеп китте...

Солтанхәким Үзәнбаш авылында торып калды...

Авыл халкы Зимагур Булатта яшәп ятучы табылдык малайга әллә нәрсә игътибар итмәде, чөнки һәркемнең үз хәле хәл иде. Кайдан килгәнен дә сорамадылар, чөнки бу дөньяда кеше табылып тора, югалып тора. Бигрәк тә — хәзер. Адәм баласының хисабы юк, үлгәнне-калганны белүче юк. Бу малайны да картның үзенә олыгайган көнендә бер юаныч булыр дип уйладылар. Бала бик әдәпле күренә иде, аны хәтта Коръән, намаз тәртибе белә икән, дип тә пышылдашып кына сөйлиләр. Нәрсә булса да, бу бала Үзәнбашка зарар китерергә тиеш түгел иде...

Солтанхәким дә бу авылны бик яратты...

Әгәр күңелендә әти-әнисе, туганнары өчен борчу булмаса,

ул сөргеннән соң мондагы тормышны җәннәт белән чагыштырыр иде. Бигрәк тә ул әтисе өчен борчылды, ул тауларны берьялгызы ничек үтәр икән дип кайгырды. Әмма ул бу хәлләрнең Аллаһтан икәнлеген яхшы белә һәм әти-әнисенең, туганнарының исән каласына өмете зур иде. Һәм ул сабыр итәргә булды. Аның биредә калуы да тәкъдирдән иде. Бу сәламәтлеге белән ул Урал тауларын үтә алмаган булыр иде, ә тотсалар, аларны Магнитка төрмәсе көтә. Авыру Солтанхәким анда түзә алмас иде. Димәк, аның биредә калуы да — Аллаһтан. Исән-сау булсалар, әти-әнисе, туганнары белән дә табышыр, иншаллаһ, бу хакта көне-төне Аллаһтан сорарга кирәк...

Шулай итеп, алар Тимербулат карт белән бергә яшәп киттеләр...

Карт аңа беренче көннән «улым» дип эндәште, малай аңа, карт үзе кушканча, «карттай» диде... Бу якларда татарлар дәү әтиләрен, ягъни бабайларын, шулай дип атыйлар икән. Бу сүз Солтанхәкимгә бик ошады, Тимербулат картка — бигрәк тә. Берара Тимербулат карт бик нык авырып алды, әллә Солтанхәкимнең чире аңа күчте, әллә вакыты җитте — ул берничә көн ут эчендә янып ятты. Солтанхәким аның яныннан китмәде, карттаен кашыклап ашатты, өшкереп эчертте, ул аны ничек тәрбияләсә, шулай эшләде. Солтанхәким кечкенәдән авылда эшләп үскән бала иде, шуңа күрә картның мал-туарын да авырсынмыйча карады, йорт-җирне дә тәртиптә тотты, ашарга да әзерләде. Һәм буш вакыты булган саен, карт янына утырып, күңелдән Коръән укыды. Тимербулат карт аның шулхәтле гыйлемле булуына исе китеп ятты, малай хәтта шактый озын «Ясин» сүрәсен дә яттан белә иде, ул картка гел шуны укыды. Терелеп аякка баскач, ул малайдан намаз тәртибен өйрәнә башлады. Бу бала аның йортына иман нуры алып килгән иде, һәм ул нур картның каткан күңелен дә эретте, йомшартты. Һәм алар, ишек-тәрәзәләрне бикләп, бергәләп намаз укый башладылар...

Солтанхәким бераз хәл җыйгач, алар бергәләп урманга, тауларга йөри башладылар, чиләк-чиләк җиләк, капчык-капчык чикләвек, гөмбә җыйдылар, Үзәнбаш, Кага суларыннан балык тоттылар. Монда Солтанхәким яңадан балалыгына кайтты. Ул болан баласы кебек таудан тауга сикерде, балык кебек, тау елгаларында йөзде, тиен кебек, биек карагай башларына менеп китте. Ул агач башларыннан бөтен дөнья күренә иде. Ә таулар... Тауларның очы-кырые юк, сырт артыннан сырт, әйтерсең лә диңгез дулкыннары...

«Әтием шушыларны исән-сау үтсен иде», — дип, малай атлаган саен дога кылды, намазларында шул хакта сорады.

Баласының эчкерсез догалары атага барып иреште...

Ул бу вакытта берьялгызы кырык сыртны кичеп килә иде...

Ә Урал тауларында Тимербулат картның үзе генә белгән җырлары яңгырый. Алар да Асылгәрәй картны алга әйди, илһамландыра, тормышка өмет уята иде...

Һай, арыслан гына ләй, киек, сикермәс,
Алларында биек тау булса.
Ир-егеткәй генә ләй, кеше, кайгырмас,
Газиз башы аның сау булса...

* * *

Этләрнең һау-һаулап өргәне, җир җимереп килгән тояк тавышлары ерагайганнан-ерагая барды.

Алда стена булып торып баскан кыя-ташлар, башы болытларга тигән тау сыртлары, кеше үтә алмаслык кара урманнар көтеп тора иде.

Асылгәрәй карт аларга каршы китте, ул аларны инде берьялгызы үтәргә тиеш иде...

Башта сибәләп кенә торган яңгыр соңга таба коеп ук ява башлады. Тауларда яңгыр шулай көтмәгәндә килеп коеп китә икән. Бу юлы Асылгәрәй карт яңгырга сөенде генә, чөнки этләр эзенә төшә алмаячаклар иде. Урман эченнән бераз баргач, ул, бер тау куышына кереп, яңгырны шунда уздырырга булды. Чөнки коеп яуган яңгыр астында барып, ул өс-башын, аяк киемен эштән чыгарырга мөмкин иде. Ә барыр юл ерак бит әле, аңа киеме дә, ризыгы да кирәк булачак...

Картка уйларын бераз тәртипкә салырга кирәк иде...

Шулай итеп, Солтанхәким калды...

Бер белмәгән кеше кулында, карагай төбендә ятып калды...

Димәк, язмышта шулай язылган булган...

Солтанхәким ялгыз калмады, аның янында төпле кеше бар. Димәк, Аллаһы Тәгаләгә аларның очрашулары кирәк булган. Бу үткен мишәр карты Солтанхәкимне ташламас, иншаллаһ, бала гына исән калсын. Хәзер Асылгәрәй карт алар өчен дога гына кыла ала, бу эшләрнең ахыры хәерле булсын, дип, Аллаһтан гына сорарга кала. Барысы өчен дә.

Әйе, бу тау араларын авыру бала белән барыбер үтеп булмас иде. Кыскасы, Магниткада калу да үлемгә тиң, качу да үлем күзе аша үтү иде. Асылгәрәй карт хәзер генә балалары, гаиләсе белән Урал тауларына кереп китүнең, качуның нәрсә икәнлеген аңлады. Әйе, бу — яшәү белән үлем арасындагы чикне кичү дигән сүз. Кырык сырт әнә шул чик аша үтә икән. Бала түгел, олы кеше дә мондый авырлыкларга түзә алмый. Әмма анда, Магнитка баракларында, үлем көтеп яту

бөтенләй өметсез. Болай әле барыбер өмет бар, ә анда синнән бернәрсә тормый. Анда син кол, тере мәет...

Асылгәрәй карт тау куышының ышык, коры почмагында намазын укып алды. Аннан әйберләрен барлап, тәртипкә китереп куйды. Иплəп кенә тотса, аның әле монда берничә көнлек ризыгы бар, ә су аяк астында гына. Димәк, хәзергә ашауэчү кайгысы юк. Тимербулат карт итен дә, ипиен дә мул тыккан, тозын, бәрәңгесен дә онытмаган. Дөнья көткән, рәт белгән кеше икәнлеге әллә кайдан күренеп тора, рәхмәт яугыры. Ул бераз капкалап алды...

Хәзер инде юл мәсьәләсен генә уйларга калды...

Тимер юл инде бик артта калды. Анда җайлысын җайлы булыр иде, әмма тотып алулары да бар. Далага, Баймак, Ырынбур ягына чыгу да куркыныч, ул тирәләрне барыбер күзәтәләр булыр. Димәк, таулар юлы кала. Анда барыбер тынычрак булачак, куа килүчеләр бу тирәдә генә булырга тиеш, эчтәрәк адәм заты булмас, алай тирән кермәсләр. Әмма бер белмәгән юл бит, барып чыга алырмы ул теге якка? Ул үзе дә алтмышның теге ягында бит инде, хәле, исәнлеге җитәрме? Ә аның башка тагы нинди юлы бар соң? Юк, шушы таулар гына кала, туган якка юл кырык сырт аша гына мөмкин. Димәк, Аллага тапшырып тәвәккәлләргә, атларга да атларга кала. Язмышында ни язылган, шул булыр.

Шушы уйлардан соң карт бераз тынычланып китте...

Инде яңгыр да туктаган, ялт итеп кояш чыккан иде. Яфракларда эре тамчылар җемелди, җирдән җылы пар күтәрелә, дөньяны кошлар чыр-чуы баскан. Якында гына күренеп торган тау сыртлары да инде алай өркетми, киресенчә, үзләренә чакырып, ымсындырып тора иде. Йа Хода, булса да булыр икән шундый матурлык! Бер сырттан икенчесенә салават күпере сузылып төшкән, әйтерсең лә фәрештәләр юлы. Тау араларындагы киң үзәнлекләрдә әллә рәшә уйный, әллә томан тарала. Ни гаҗәп, тауның бу як сыртында яңгыр да юк, җир дә коп-коры, әйтерсең лә табигать юлаучы картның килүен көтеп торган һәм атлас келәмен җәеп куйган. Хәл җиткәнчә атла да атла гына. Хәрәкәт ит, алга бар. Бу барыбер сөргендә үлем көтеп яту, мәсхәрәләнеп яшәү булмаячак. Бер көн булса да, кеше булып, иректә яшәп калу булачак. Күкрәк тутырып саф һава сулау, авыз тутырып саф чишмә суы эчү, үзең теләгән якка атлау, үзең теләгәнчә яшәү. Борынгы татарлар юкка гына дөньяның бер башыннан икенчесенә менә шулай йөрмәгәннәрдер инде. Ирек, бәйсезлек хисе шулай йөрткәндер аларны. Алар салып калдырган сукмактан менә хәзер Асылгәрәй карт атлый. Заман башында алар үткән кырык сыртны менә хәзер ялгыз татар ире үтә...

Ни гаҗәп, аның юлында хәзергә авыллар да, кешеләр дә, хәтта җәнлек-мазар да очрамады. Ул шулай берьялгызы тәмам арыганчы барды да барды. Чираттагы тау сыртын үзәнлек буйлап үтте, тарлавык аша аргы якка чыгып, шунда төн кунарга тукталды. Каршында тагы яңа таулар җәйрәп ята иде. Араларында киң үзәнлекләр, шаулап аккан тау елгалары, кара урманнар. Карт көчен һәм ризыгын саклап кына тотарга булды. Аңа хәзер артык кабаланырга, артык арырга һәм эштән чыгарга ярамый иде. Саклык чараларын да онытмаска кирәк, кеше булмаса, җәнлек-мазар куркытуы бар, ә аның кулында таяктан кала берние юк. Шуңа күрә ул якты күздә генә атларга, караңгы төшә башлау белән төн куну турында кайгыртырга тиеш иде. Ә монда тау куышлары күп, урманнарда да ышык урыннар җитәрлек, әйтерсең лә барысы да юлчылар өчен җайлап куелган. Әкренләп ул да боларның җаена төшенер, рәтен табар, Алла теләсә...

Асылгәрәй карт чираттагы тау куышына җайлы гына кереп урнашып, инде ятарга әзерләнеп йөри иде, урам якта сәер кыштырдау тавышы ишетеп, сагаеп калды. Анда нәрсәдер, сәер өстерәлеп, куыш авызына таба килә иде. Карт тизрәк кулына таягын алды, стенага сыенып, керүчене көтә башлады... Караңгыда ялтырап янган ике күзне күреп, ул сискәнеп китте — аның каршында әллә бүре, әллә эт басып тора иде. Җанвар ырлап куйды, аннан йөрәкне телеп чинап-улап җибәрде. Бу үзәк өзгеч тавыштан картның тәннәре калтырап китте, ул, күзен алмыйча, җанварга текәлде. Менә төнге кунак авырлык белән генә куыш авызына аркылыга сузылып ятты. Карт аның хәрәкәтләрендә ниндидер сәерлек сизде, җанвар нидәндер газаплана кебек иде. Карт аңа игътибар беләнрәк карады һәм төнге эңгердә ялтырап яткан тимер кисәген күрде. Һәм ул барысын да аңлап алды — җанвар капкынга эләккән иде, һәм ул, аны өстерәп, тау куышына хәтле килеп егылган...

Карт ирексездән аның хәлен үзенеке белән чагыштырды...

Алар икесе дә, капкыннарын өстерәп, тау арасында качып йөриләр иде...

Карт җанварга игътибар беләнрәк карады — ул этне дә, бүрене дә хәтерләтә иде. Бәлки, кыргыйланган эттер, хуҗасыз калган нигезләрдә күп бит алар хәзер. Ни булса да, капкынын сөйрәп, ул куыш авызына килеп егылган, хәзер Асылгәрәй картның юлында аркылы ята. Хәзер Асылгәрәй карт үзе тау куышында капкында калган кебек. Әлбәттә, аңа бу мескенне капкыныннан ычкындыру берни тормый, ә ул соңыннан аның үзенә ташланса? Ботарлап атса? Хәзер карт бу тау куышыннан җиңел генә чыгып та китә алмый, юлында, аркылы сузылып, яралы җанвар ята. Бәлки ул, кеше исе

сизеп, аның янына ярдәм эзләп килгәндер? Бу бәладән аны хәзер кеше генә коткара ала бит, әмма аны бу хәлгә калдыручы да адәм баласы шул...

Карт әкрен генә яралы җанвар янына якынлашты...

Якыннан ул кыргый эткә охшаган иде, димәк, кешегә ташланмаячак. Ялтырап янган утлы күзләре бүрене дә хәтерләтә. Ул картка әкрен генә ырлап куйды, әмма юлдан китмәде, башын алгы тәпиләренә салып, хәлсезләнеп сузылып ятты. Арткы тәпиен шартлатып капкын кыскан, аннан кан саркып тора иде. Җанварның авыр итеп тын алганы ишетелеп тора, вакыты-вакыты белән ул чинап-сулкылдап та куя.

Карт җан иясенең бу газабына түзә алмады, кулларын капкынга сузды.

Җанвар исә, башын күтәрми генә, яткан җирдән аны күзәтә, ә күзләреннән мөлдерәп яшь ага. Җан иясенең шулхәтле газапланганын ул тыныч кына карап тора алмады, капкынга тотынды. Тимер келә җанварның тәпиенә суелып диярлек кергән, мәңге ычкындырмаска каптырган иде. Җанвар белән ипләп кенә сөйләшә-сөйләшә, карт капкынны ычкындыра башлады. Хайван әйтерсең аны аңлый, вакыт-вакыт чинап-сулкылдап җавап бирә, адәм баласының үзен коткаруына өмет итә иде...

Ниһаять, карт капкынны ычкындырды.

Җанвар шунда ук җиңеләеп калган арт аягын тартып алды. Әмма ул әле урыныннан кузгала алмады, каты авырту аны таш идәнгә сузылып ятарга мәҗбүр итте. Карт күреп тора — җанвар ач иде, чөнки мондый йөк белән ничек ауга йөрисең? Ул теге көнне Тимербулат карт биргән тавык сөяк-санакларын, җыеп, җанвар алдына салды. Тегесе, авыртуын да онытып, ризык өстенә капланды. Ачлык бөтенесенә караганда да көчлерәк булып чыкты.

Ашап туйгач та, җанвар урыныннан кузгалмады, мәгарә авызында ятып калды. Карт исә, иң ерак почмакка барып, Аллага тапшырып йокларга ятты. Бу җанварның үзенә тимәсен ул күңеле белән сизенә иде, чөнки эчкерсез ярдәмне хайван да аңлый бит. Төнлә тау арасында бәрелеп-сугылып йөргәнче, монда кунуың яхшырак, чөнки анда моннан куркынычракларны да очратырга мөмкин. Ике аяклылары бигрәк тә яман, аларны тегендә күп күрде инде Асылгәрәй карт. Андый адәмнәргә караганда, җанвар белән бергә төн кунуың яхшырак...

Төн бик тыныч үтте...

Таңны алар һәркайсы үз урынында яткан килеш каршы алды. Яктыда Асылгәрәй карт яралы җанварны яхшылабрак карады, бу кыргый эт иде. Шуңа күрә курыкмыйча кеше янына килгән инде ул мескен, аннан ярдәм көткән. Алай да

саграк булырга кирәк, ул таулар арасында бүре булып яшәргә өйрәнгән инде, чөнки монда башкача исән калырга мөмкин түгел. Карт тагы иплəп кенә җанвар белән сөйләшә башлады, аңа төрле исемнәр белән эндәшеп карады, алдына кичтән калган сөякләрне китереп салды.

— Мин сиңа Сарбай дип эндәшермен, ярыймы? — диде ул, кыргый этне үз тавышына ияләндерергә тырышып. — Теләсәң, бергә китәрбез, теләсәң, монда калырсың. Ә миңа кайтырга кирәк, Сарбай, атларга кирәк… Менә шулай, туган…

Ул, куркытмыйча гына, сузылып яткан этнең аяк очыннан тышка чыкты…

Әле кояш чыкмаган, әмма таң яктысы инде бөтен Урал тауларына җәелгән иде. Дөнья инде уянган, яши башлаган, Асылгәрәй картка да алга таба атларга кирәк иде. Каршыда әнә тагы бер сырт, таш кыялы шәрә тау. Карт инде бу тауларны аера башлады — ташлы кыяга күтәрелүе бигрәк тә авыр иде. Ни тотынырга агач заты юк, ни аяк асты тигез түгел, теләсә кайсы вакытта таш белән бергә түбәнгә очарга мөмкин. Бу таш сыртны әйләнеп үтәргә юл да күренми, бөтен якта, бер-берләренә терәлеп, таулар тезелеп киткән. Димәк, тагы аларга каршы китәргә кала, юл бары тик таулар аша гына бит…

Карт, елга буена төшеп, битен-кулын юды, тәһарәтләнде, кыйблага карап иртәнге намазын укып алды. Аннан бераз тамак ялгады. Хәзер инде юлга кузгалырга да була иде…

— Хуш, Сарбай, мин китәм, туган, — диде ул аңа якын итеп.

Эт башын күтәреп карады, аннан әкрен генә кузгалды һәм аягына басып карады. Арткы тәпие әле басарлык түгел иде, аны өстерәп диярлек Сарбай Асылгәрәй карт артыннан иярде.

— Ә, син дә минем белән барырга булдыңмыни? — диде карт, шуны гына көткәндәй куанып. — Әйдә, әйдә, миңа иптәш булырсың. Тик бу аяк белән ерак китә алырсыңмы икән син?

Ул, туктап, этне көтеп алды.

Аны иплəп кенә үз янына чакырып китерде, яралы тәпиен учына алды. Яра әллә ни зур түгел иде, әмма аны барыбер юып бәйләргә кирәк. Карт яраны сак кына чишмә суы белән юды, эт, аңлагандай, сабыр гына ятып торды. Аннан карт нарат чәере кырып алып, аны ярага ябыштырды. Эт, барысын да аңлагандай, монысында да тик торды, өрмәде дә, чинамады да. Ул бу карт кешегә ышанган иде инде. Аннан Асылгәрәй карт чишмә буеннан үги ана яфраклары җыеп алып килде, аларны яра өстенә салып, чүпрәк кисәге белән ныклап бәйләп куйды. Башта бераз сиздерсә дә, берничә көннән яра төзәләчәк иде…

— Йә, ярар, кузгалыйк алайса, — диде карт, сөйләшергә иптәш табылганга куанып. — Хәзергә әкрен генә бар минем арттан, аннан алга чыгарсың, үзең теләгәнчә чабарсың... Мин дә тиз бара алмыйм инде хәзер, синең кебек кенә теркелдим...

Кара урманнар гөжләп, тау елгалары шаулап, кыя-ташлар артка чигенеп, аларга юл бирделәр. Карт белән эт, үзләренә куелган капкыннан ычкынып, үзләре теләгән юлдан баралар иде. Монда инде бөтенләй башка дөнья. Монда бары тик таулар гына хуҗа, бу таулар иле иде. Монда инде авыллар да юк, кешеләр дә күренми, монда төрмәләр дә, зур төзелешләр дә юк. Бу тауларның үз тәртибе, үз кануннары, үз тарихы бар... Бу мәгъруур таулар теләсә кемгә капкаларын ачмыйлар, теләсә кемне үзләре аша уздырмыйлар иде.

Асылгәрәй картка исә алар, артка чигенеп, юл бирделәр...

Адәм баласының артка чигенмәсен алар да аңладылар, ахры...

Әмма аның өчен бу тауларда сынау бетмәгән иде әле...

Каршыдагы кыя-таудан Асылгәрәй карт белмичә генә шүрләмәгән икән...

Аннан әллә нинди көч һәм дәһшәт бөркелеп тора, ул әйтерсең лә адәм баласын тагы бер тапкыр сынап карарга тели иде. Кайсы якка карасаң да — биек кыя, әйтерсең лә таш капчык. Асылгәрәй карт, хәйран калып, астан аларга карап тора. Ничек менәр ул анда, ничек теге якка төшәр? Мәрмәр кыя ташлары шулкадәр шома, аларда хәтта җил дә үзенә урын тапмый, җиргә төшеп уларга мәҗбүр була. Әйтерсең лә җил дә адәм баласы белән аңа ияргән җанварны кисәтергә тели. Алга да, артка да, ян-якка да юл юклыгын әйтергә тели...

Моны күреп, карт үзе дә туктап калды, Сарбай да аның аяк очына килеп ятты. Кыя башларында исә тау бөркетләре бөтерелә, алар тын гына бу таш капчыкка килеп эләккән җан ияләрен күзәтәләр. Бу башсыз сәяхәтнең ахырын көтәләр. Чөнки аларның тарихында бу кыя-тауларны кичеп чыккан кеше юк әле. Чөнки моннан чыгу юлы юк. Юк!.. Юк!.. Юк!.. Ә чыгарга кирәк, чөнки бу кыялар артында — туган як, туган җир...

Асылгәрәй карт, тау итәгендәге сирәк чыршыларга тотына-тотына, өскә таба менә башлады. Сарбай шикләнеп кенә аның артыннан иярде, чөнки кыя-ташлар арасында юл юклыгын ул да күрә иде. Асылгәрәй карт исә таш өстендә үскән чыршы-карагайларны күреп таң калды, үзенекен уйлады, үзен уйлады. Чөнки биредә җир юк дәрәҗәсендә иде, баскан саен таш, тамыр җибәрергә урын юк. Ә алар үсә. Тоташ таш арасында да, ярык табып, орлык чәчәләр, тамыр җибәрәләр һәм күккә үрлиләр...

Асылгәрәй карт бу карагайларны татар халкына охшатты...
Татар да шундый бит: кайда орлыгы төшсә, шунда тамыр җибәрә. Ком чүлендә дә, сахра-далада да, кыя-тауларда да. Һәм яшәү өчен җан тартыша... Менә бу тау араларында да, сибелеп, татарлар яшәп ята. Анда бер авыл, монда бер авыл. Каян килеп чыккан алар бирегә, нәрсә тота аларны тау-таш арасында? Менә шушы чыршы-наратлар кебек, заман җилләренә чәнечкеле энәләрен тырпайтып, тау арасында да татар булып, кеше булып яшәп яталар...
Югарыга менгән саен, чыршы-карагайлар да сирәгәйде. Алга таба мүк каплаган ташлар гына калды. Көн дә сизелерлек салкынайтты, суык җил исә башлады. Ә аяк астында бары тик таш, таш, таш. Түбәгә хәтле әле шактый ерак, ә кыяташлар арасыннан инде үтәрлек түгел. Кая барып төртелсәң дә, каршыңа шулар чыгып баса. Өстә исә каһкаһә белән тау бөркетләре көлә. Аста җил өзгәләнә. Чөнки бу затларның капкынга килеп эләгүләрен белә алар. Аннан инде чыгу юлы юклыгын да яхшы беләләр...
Ул арада, биткә бәреп, әллә яңгыр, әллә кар ява башлады...
Карт өшеп китте, җылынасы килеп ышык урын эзләде. Әмма биредә хәтта тау куышлары да күренми иде. Ашарга да инде бетеп бара, икесенә бүлеп ашый торгач, ризыклары шактый тиз кимеде. Әмма иң авыры — югарыда су юк, чишмәләр барысы да аста калды. Сыртны кичсәң, бар да бардыр, әмма бу текә кыяга ничек менәсең?
— Йә, нишлибез, Сарбай? — диде ул, тәмам гаҗиз булып. — Эләктек бит без синең белән капкынга. Аска кире төшәр идең, анда да дүрт яктан кыя-тау. Сөягеңне дә таба алмаслар. Исән калу өчен бер генә юл бар, туган — ничек тә бу сыртны кичү, теге якка чыгу.
Сарбай, колагын тырпайтып, аны тыңлап торды да кинәт кенә уңга карап ырлый башлады. Аның сыртындагы йонннары кабарган, тәне дер-дер килә, әйтерсең лә ул таш арасында койрыклы шайтанны күргән иде. Асылгәрәй карт та шул якка борылып карады һәм тынсыз калды... Кыя башында, алар өстенә сикерергә әзерләнеп, зур тау мәчесе — селәүсенрысь сузылып яткан иде. Аның чуар тиресе тартылып килгән, очлы колаклары тырпайган, яшел күзләре ут чәчеп яна. Менә ул кискен бер хәрәкәт ясады да ук булып Асылгәрәй карт өстенә атылды. Карт аның пычак кебек үткен тешләрен, ыргактай кәкре тырнакларын гына шәйләп өлгерде. Ике арага, яшен ташыдай атылып, Сарбай килеп керде, ерткыч бөтен авырлыгы белән аның өстенә килеп төште... Икенче бер мизгелдә Сарбай белән селәүсен, бугазга-бугаз килеп, таш өстендә ауныйлар иде инде...
Бөтен тирә-як ырлаган, хырылдаган, чинаган тавышлар

белән тулды, һавага кисәк-кисәк җон, тире очты... Әле Сарбай, әле селәүсен аста калды. Өстә исә, үз чиратларын көтеп, тау бөркетләре бөтерелә иде. Алар бу канлы яуның ахырын көттеләр. Асылгәрәй карт та, аңына килеп, кулына тиз генә зур таш кисәге алды, аның белән ерткычка кундыру җаен эзли башлады... Инде селәүсен, өскә чыгып, хәлсезләнгән Сарбайга азау тешләрен батырам дигәндә, Асылгәрәй карт таш белән аның башына сукты... Селәүсен Сарбайдан тырнакларын ычкындырды һәм, тәгәрәп, җиргә барып төште. Калганын инде Сарбай үзе эшләп бетерде. Моны күрмәс өчен, Асылгәрәй карт бер читкә барып утырды. Ул үзенең әле яңа гына үлемнән калганын аңлады.

Ул арада Сарбай, тау мәчесенең эшен бетереп, картның аяк очына килеп ятты. Аның җоннары шактый таланган, берничә җирдән тиресе кисәк-кисәк кубарылып чыккан иде. Карт, рәхмәт әйтеп, аның сыртыннан сыйпады, Сарбай моңа каршы ялкау гына ырлап куйды, урыныннан кузгалмады. Ул да бик арыган, ул да бүген үлемнән калган иде...

Бу хәлләрдән соң ятып бераз ял итеп алдылар. Әмма монда озак калып булмый иде, чөнки салкын җил сөяккә хәтле үтә, монда төн чыгарга да куркыныч. Карт, ярдәм эзләгәндәй, тагы күккә карады. Ул үзләреннән бераз читтә тау бөркетләренең җиргә төшкәнен күрде. Тагы ни булыр икән, дип, ул сак кына шул якка таба китте. Сарбай анда селәүсеннең үләксәсен илтеп ташлаган икән, бөркетләр шуңа җыелганнар. Бу урын кыя артында булып, карт аны баштарак күрмәгән иде. Килеп җиткәч, каршындагы манзарадан ул хәйран калды. Кыя артында зур үзәнлек башланып китә, ә анда аска таба юл сузылган. Шушыннан туп-туры барып, тауның теге ягына төшеп җитәргә була иде. Әйтерсең бу турыда тау үзенең ишекләрен ачкан һәм аннан теләгән кешеләрен генә уздыра иде...

— Сарбай, Сарбай, киттек тизрәк, туган! — дип кычкырып җибәрде карт, шатлыгыннан нишләргә белмичә. — Менә бит безгә дигән юл, Алланың рәхмәте. Аста әнә елга да агып ята. Төшик шунда тизрәк.

Сарбай килеп җиткән арада, карт хозурланып тирә-якка карады...

Әнә тау диңгезе артында кызарып кояш батып килә...

Алсу шәфәкъ Урал тауларыннан Зәйтуганга хәтле сузылган. Әмма кояш анда әле соңрак байыячак, ул әле Зәйтуганга таба тәгәрәп бара гына. Асылгәрәй карт кебек кояш та илгә кайтып бара. Әмма ул аңа караганда илгә иртәрәк кайтып җитәчәк. Асылгәрәй картка ул көнне күрер өчен әле атлыйсы да атлыйсы, шушы кырык сыртны исән-имин үтеп бетерәсе...

Шулай әвәләнеп агачлар арасыннан әкрен генә аска төштеләр. Сарбай төшә-төшешкә елга буена йөгерде, карт үзе дә шунда ашыкты. Аның инде эчәсе дә, ашыйсы да килә иде, арыганлык та бүген үзен нык сиздерде. Шуңа карамастан карт елгада балык тотып карарга булды, аның, учак ягып, җылы ризык әзерлисе килә иде. Алланың рәхмәте, суга кереп үскән агач төпләрендә Сарбай белән бераз шапылдый торгач, картның күлмәгенә берничә балык йөзеп керде. Ул тизрәк яр буендагы ышык урынга учак көйрәтеп җибәрде, балыкларны таш өстенә куеп, бераз кыздырып алгандай итте. Аннан Тимербулат карт биргән тоз һәм ипи калдыгы белән тәмләп ашап та куйды. Сарбай исә бүгенгә тук иде, ул, учак янына сузылып ятып, күзләрен йомды. Аның инде бераз ял итеп алырга да хакы бар иде...

Асылгәрәй карт төнне шушында уздырырга булды...

Агымсу белән бит-кулларын юды, тәһарәт алды, кыйбла ягына карап кичке намазын укыды. Аллаһ аны бүген үлемнән саклап калды, әмма фаҗиганең янәшә йөрүен дә күрсәтте. Биредә адым саен билгесезлек, адым саен куркыныч, адым саен үлем очрарга мөмкин иде.

Асылгәрәй карт кырык сыртның әле чиреген дә үтмәгән иде...

Алда исә аны тагы да зур сынаулар һәм хәвеф-хәтәр көтеп тора иде...

* * *

Абзар ишеге төбендә сәер кыштырдау ишетеп, Сабира сыер сауган җиреннән туктап калды.

Хәзер авылда кемнәр генә йөрми — карагы да, сукбае да, вәкиле дә, шымчысы да. Бөтен халыкны мал-туары белән колхозга куып керттеләр, ә колхоз дигәненең мал абзары да юк. Шуңа күрә һәркем эре малын үзендә тота, сөтен-маен хөкүмәткә бирә. Абзарлардан сыерларны урлап алып чыгып китү очраклары да күбәйде, бу мал-туар хәзер колхоз малы исәпләнә, аны урлаткан өчен, хуҗаларны хөкем итәләр. Кемгә — төрмә, кемгә — Себер, авылда инде эшләргә кеше дә калмады, җыен ярлы-ябага...

Сабира, эшен туктатып, сагаеп тыңлап тора башлады...

Тукта, кемдер «кызым» дип дәште түгелме соң? Әллә, Ходаем. Әллә, Ходаем, әнисе кайтканмы, соңгы вакытта шулай качып кайтучылар еш күренә башлады бит авылда. Шайтан Шакир да көн дә бер килеп әйләнеп китә, нидер иснәнә, нидер белергә тели. Берничә тапкыр: «Сезнекеләр күренмәдеме монда?» — дип тә сорап куйды, әмма артыгын ычкын-

дырмады. Сөрелгәннәрнең берничәсе шулай качып кайткан иде, Шайтан Шакир аларны шунда ук тотып бирде. «Бөгелмә төрмәсеннән кире озаттылар», — диделәр...

Сабира урыныннан кузгалды һәм сак кына ишек төбенә килде...

Анда, иске сәләмәләргә төренеп, бер хатын-кыз ята иде. Йөрәге нидер сизенеп, Сабира аның өстенә иелде һәм куркуыннан кычкырып җибәрде — абзар ишеге төбендә, аңсыз хәлдә, аның әнисе ята иде. Әнисенең йөзе саргаеп сулган, иреннәре күгәреп көйгән, яланаяклары сыдырылып канап беткән. Сабира аны тиз генә култык асларыннан күтәреп алды, салам өстенә алып килеп салды. Үзе су алырга йөгерде. Әнисенең башын сак кына тотып, аның иреннәренә су тидерде, битен-күзен чылатты. Сабираның кайнар яшьләре әнисенең битенә тамды, һәм Маһинур абыстай күзләрен ачты. Шунда гына ул үзенең авылга кайтып җитүенә ышанды, аның янында кызы Сабира басып тора иде...

Ул арада өйдән Гариф кияү дә чыгып җитте, алар бергәләп Маһинур абыстайны өйгә алып кереп салдылар. Капка-ишекләрне келәгә бикләделәр, тәрәзә пәрдәләрен тартып куйдылар. Анасының ач икәнлеген сизеп, Сабира аны шунда ук кашыклап ашата башлады. Бер-ике кашык шулпа капканнан соң, Маһинур абыстай арып урынга ятты. Ул, кемнедер эзләгәндәй, карашы белән өй эчен йөртеп чыкты. Аның тел тибрәтеп әйткән беренче сүзе ире һәм балалары турында иде.

— Атаң... кайтмадымы, кызым? — диде ул, ниндидер өмет белән. — Балалар... күренмәдеме?

— Юк, әни, — диде Сабира гаҗәпләнеп. — Нәрсә, кайтырга тиешләр идемени?

— Качтык без аннан, кызым, — диде Маһинур абыстай пышылдап кына. — Адәм түзәрлек түгел анда. Балалар барысы да үлеп беткәнче качыйк, дидек. Инде исән-сау кайтып кына җитә күрсеннәр...

Маһинур абыстай һаман иренең һәм балаларының кайтып җитәселәренә өметләнә иде әле. Ул кайтып җитте бит, димәк, башкалар да шушы юлда. Инде, Раббым, алар белән исән-сау күрешергә насыйп итсен.

Икенче көнне иртәнге якта ук мунча ягып җибәрделәр...

Маһинур абыстайның өс-башына да, үзенә дә карарлык түгел иде...

Коры сөяккә калган әнисен Сабира елый-елый юындырды. Чиста өс-баш кидергәннән соң, Сабира аның сәләмәләрен тизрәк уткаякты. Хәзер тикшерү-күзәтү күп, бернинди эз калдырырлык булмасын. Ә менә әнисен кая куярга, кая яшерергә? Шайтан Шакир, көнаралаш диярлек бер килеп, иснәнеп китә, әрсезләнеп өйгә хәтле бәреп керә. Мыр-мыр

килеп, абзар тирәләрен әйләнә, бәрәңге бакчаларын чыгып карый. Димәк, ул аларның Магниткадан качканнарын белә, аңа хәбәр иткәннәр булып чыга. Хәзер ул аларның кайтып керүләрен сагалап йөри. Әйтсәң, «Кеше аермаган тәреләр, мин сезнең нәселегезне төрмәдә чертәм!» — дип акыра, сүгенә башлый. Равилнең Вәсимәне алып качуын кичерә алмый, күрәсең. Инде авылның үзе кебек бер ярлы кызына өйләнде дә бит югыйсә, тынычланырга да бик вакыт. Юк, һаман Морза Мирзаяннар нәселенә каныга, һаман үч алу белән яна...

— Равил абыйларың Бөгелмәгә кайтмаганнар икән, — дип, алар турында үзе сүз башлады Маһинур абыстай. — Аларга да кулы җиттеме әллә Шайтан Шакирның? Берәр хәбәрләре юкмы соң?

— Алар теге китүдән кайтмады бит, әни, — диде Сабира шыпырт кына. — Ташкент якларында булырга тиешләр, күрүчеләр булган...

— Аллага шөкер, алар булса да котылганнар икән, — диде Маһинур абыстай, җиңел сулап. Бераз тын гына яткач, өстәп куйды: — Туганнарыңның яртысы юк инде бу дөньяда, кызым. Рәйсә юлда барганда ук тифтан үлде. Сажидәне эштә кирпеч басып үтерде. Сәгыйть ачтан үлде. Гыйлемгәрәйне качканда атып үтерделәр. Инде башкалары исән була күрсен. Гайшәбикә, Солтанхәким, Мәрзия...

Бу хәтле кайгылы хәбәрдән Сабира шашып калды...

Башта ул әнисен әллә саташамы икән дип уйлады, ышанасы килмәде...

Мөмкин хәлме — бер ел эчендә дүрт туганы юк! Узган җәй алар авылдан үз аяклары белән чыгып киттеләр, хәзер каберләре дә билгесез. Төпчек сеңлесе, ут борчасы Рәйсә... Чәчәкләр арасында гына үскән оялчан Сажидә... Ярдәмчел, тырыш энесе Сәгыйть... Коръәнне яттан белгән гыйлем иясе Гыйлемгәрәй... Шулар инде дөньяда юк, мөмкин хәлме бу? Әнисе ничек түзгән бу хәлләргә, ничек акылын җуймаган, шушы хәтле хәсрәт белән ничек кайтып җитә алган ул? Хәер, әнисенең кара чәчләре ап-ак булган, алсу йөзе саргайган, күзләренең нуры сүнгән бит, ул әйтерсең лә инде башка дөньяда яши... Киткән балалары янында...

Сабира әнисен кочаклап үксеп елап җибәрде...

Инде әнисен генә яңадан килеп алмасыннар, ул бу хәлләргә инде түзә алмаячак. Аның чыкмаган җаны гына калган бит инде. Ничек хәзер аны саклап калырга, ничек Шайтан Шакирдан яшерергә? Ничек бу хакта үзенә әйтергә?

Маһинур абыстайны мич арасындагы чаршау артына алып кереп салдылар...

Балаларга әбиләренең кайтуы турында беркемгә бернәрсә әйтмәскә куштылар. Капка-ишекләрне көндез дә бикләп

тота башладылар. Әмма кеше хәтле кешене бәләкәй генә авыл өендә яшереп тотып буламы соң? Аның әле күршеләре килеп керә, әле бригадиры, әле салымчысы сугыла. Шайтан Шакирны инде әйткән дә юк, ул бу тирәләргә эзен суытмый. Ул тыкрык башында күренүгә, каршына, капка төбенә үк йөгерешеп чыгалар, әле тегеләй, дип, әле болай, дип, тизрәк борып җибәрергә ашыгалар. Әмма алга таба аны гел болай алдалап йөртеп булмаячак. Димәк, әнисен кая да булса яшерергә кирәк, аны алга таба өйдә тотып булмаячак. Ә кая яшерергә? Авыл кешесенең бар булганы өй дә абзар, баз да мунча бит инде аның. Карчык кешене мал янына абзарга кертеп булмый, салкын базга да төшә алмый ул. Димәк, мунча кала. Әмма моны ничек әнисенең үзенә әйтергә? Хәтере калмасмы, дөрес аңлармы?

Әмма Сабира әнисенә боларны аңлатып өлгерә алмады, капка дөбердәткән тавыш ишетелде... Пәрдә читләрен күтәреп, тәрәзәдән карадылар — капка артында Шайтан Шакир басып тора, үзе дөнья бетереп акыра, сүгенә иде. Моны күреп, Сабираның коты чыкты, бер ишеккә, бер тәрәзәгә килеп капланды, әнисен кая куярга, кая яшерергә белмәде. Чөнки бу юлы Шайтан Шакир өйгә кермичә китмәячәк иде...

Кызының өзгәләнүен күреп, әнисе үзе аңа ярдәмгә килде:

— Түбән өйгә төшер, кызым, — диде ул, чаршау артыннан чыгып. — Аннан эзләргә башы җитмәс мәлгуньнең...

Сабира тиз генә идән капкачын ачты һәм әнисен өй астына төшерде...

Анда инде иске бәрәңге беткән, яңасы әле алынмаган, җир идән буш иде. Сабира ашыга-ашыга өйне тәртипкә китерде, әнисенең мич арасындагы урынын җыештырып куйды, киемнәрен яшерде. Аннан соң йөгереп чыгып капканы ачты.

— Нәрсә көпә-көндез капкалар бикләп утырасыз монда?! — дип акырып, Шайтан Шакир туп-туры өйгә бәреп керде.

Ул, нидер сизенеп, тиз генә өй эчен әйләнеп чыкты, чаршау артларын ачып карады. Берни таба алмагач, күн итекләрен дөпелдәтеп, идән буенча йөренә башлады. Аннан ашыгып ишегалдына чыгып китте, абзар тирәләрен әйләнеп килде, мунча ишеген ачып карады. Анда да эзләгәнен таба алмагач, баз капкачын каерып ачып ташлады, башын тыгып, аска карады. Ул нәрсәдер сизенә, әмма эзләгәнен таба алмый иде...

Шайтан Шакир, яман сүгенеп, капкага таба китте.

— Берәрсен яшергәнегезне генә белим, барыгызны да төрмәдә черетәм, — диде ул, аягы белән капкага китереп тибеп. — Моннан ары көпә-көндез бикләнеп утырасы булмагыз! Совет властен капка төбендә тотарга не сметь!

— Хәзер теләсә кем йөри, шуңа күрә бикләп куйган идек, — диде Сабира aклангандай. — Колхоз малына тимәсеннәр, дибез, Гарифҗан да шулай куша...

Мондый вакытларда Сабираның бөтен коткаручысы — ире Гариф...

Авылның ярлысы булгач, аңа берничек тә бәйләнә алмыйлар, хәтта Бөгелмәдә дә аны беләләр, гражданнар сугышы батыры белән исәпләшергә мәҗбүрләр. Юкса Шайтан Шакир аларны әллә кайчан кара исемлегенә керткән иде инде, Бөгелмәдән кире бордылар. Шулай итеп Зәйтуганда Асылгәрәй хәзрәтнең нәселен бетерергә уйлаган иде, барып чыкмады...

Шайтан Шакир сүгенә-сүгенә авыл советына таба китте...

Авыл советы дигәннәре шул Асылгәрәй хәзрәттән калган ике катлы йорт иде, анда колхоз идарәсе дә, почтасы да бергә урнашкан. Башта аны клуб итәргә уйлаганнар иде, әмма үзләренә утырырга урын булмагач, идарә итеп алдылар, җыен әтрәк-әләм шунда кереп тулды. Өйдәге бөтен байлыкны берәм-берәм үзләренә ташып бетерделәр, умарталарны Бөгелмә урысларына сатып эчтеләр, чөнки аларны тоту Шайтан Шакирлар кулыннан килми иде. Бакча тапталып бетте, җимеш агачларын беркем карамады, ә чәчәк түтәлләре урынында шайтан таягы котыра... Ә клубны Асылгәрәй хәзрәтнең таш мәчетеннән ясадылар. Чөнки болай эшләү совет идеологиясенә бик тә туры килә иде...

Имеш, заманында монда дин дип халыкның миен череткәннәр, ә хәзер бәхетле совет яшьләренең күмәк җырлары яңгырый. Намаз урынына надан татарлар ду килеп бии, кыйбла тарафында — сәхнә, мөнбәрдә — агитатор. Монда һәр кичне диннән көлеп кичәләр уздырыла, театрлар куела. Янәшәдәге мәдрәсә йортыннан совет мәктәбе ясадылар, чөнки укытырга башка урыннары юк иде. Монда да беренче сүз совет властен мактаудан, иске заманны сүгүдән башланды. Зәйтуганда татар балаларын дингә каршы котырту чоры башланып китте. Һәм Асылгәрәй хәзрәтләрдә җир себереп йөргән Шайтан Шакир хәзер шуларның барысына да баш, бөтен авылга хуҗа иде...

Шайтан Шакир мәчет урамына кереп югалгач кына, Сабира әнисен түбән өйдән чыгарды. Барысы да аңладылар — Шайтан Шакир качакларны эзләп йөри иде. Һәм ул монда хәзер гел киләчәк, иснәнәчәк. Бу хәлләргә бигрәк тә Мәһинур абыстай бик борчылды, чөнки ире белән балалары кайтып керсә, яңадан Шайтан Шакир кулына килеп кабарлар дип коты чыкты аның. Ул аларны теләсә кайсы вакытта тотып алачак һәм яңадан төрмәгә тыгып куячак. Аннан аларны тагы сөрген көтә, Магниткаының бозлы, бетле бараклары

көтә, газаплы ач тормыш көтә. Юлга чыкканда, алар бу хакта уйламаганнар иде, алар өчен иң мөһиме — сөргеннән котылу һәм Зәйтуганга кайтып егылу иде. Ә монда менә нәрсәләр көтеп тора икән бит аларны...

— Монда мәхшәр хәзер, әни, — дип әйтеп куйды Сабира, аның уйларын сизгәндәй. — Сездән соң авылдан бик күп кешеләрне сөрделәр бит. Баен да, урта хәллесен дә, намаз укыганын да, намазсызларны да. Иң зур исемлек безнең авылдан булган, диделәр, район планын шулар тутырган. Теге вакытта мәчет манарасын кистермәгән өчен дә үч алганнар, халыкның күтәрелүе өчен дә...

— Тегендә күрдек без аларның күбесен, — дип, аны раслады Маһинур абыстай. — Анда иң күп халык Әлмәт, Бөгелмә якларыннан иде шул. Аларның кайберләре җәйгә чыгу белән качып та карады. Болай булгач, аларны да шушы көн көтә икән, яңадан төрмә, диюем.

— Әйе, әни, качып та күпме кеше кайтып карады. Кайткан берсен тотып җибәрәләр. Хәзер бөтен авылга Шайтан Шакирлар хуҗа бит. Эшләргә кешеләре юк, бер җирдә тәртип юк, эшләре бармагач, бөтен җирдән дошман эзлиләр. Бөтен нәрсәне, хәтта тавык-казларга хәтле җыеп, колхоз ясадылар. Безнең өйне нәҗескә батырып бетерделәр, ул якка карый да алмыйм хәзер. Нәрсә белән бетәр бу хәлләр, белмим...

Маһинур абыстай гөл-чәчәкләргә күмелеп утырган өен, ялт иткән хуҗалыгын күз алдына китерде. Асылгәрәй хәзрәт кая гына барса да, аннан гөл орлыгы алып кайта иде шул. Аның балалары шул гөлләр арасында үстеләр. Каршыда гына мәчет иде, аннан көнгә биш тапкыр азан тавышы яңгырый, ир балалар барысы да шунда ашыгалар. Асылгәрәй хәзрәт уллары Гыйлемгәрәйне шунда имам итеп калдырырга әзерли иде. Еллар ничек буталчык булса да, ул балаларына Коръән өйрәтте, барысын да намазга бастырды, тәртиптә тотты. Авылда аларның балаларыннан әдәпле, аларның балаларыннан укымышлы балалар юк иде. Һәм шушы гөл оясын, былбыл оясын туздырдылар да ташладылар... Нәрсә өчен, кемгә кирәк булды бу талау? Кем отты моннан? Маһинур абыстайның моңа җавабы юк иде...

Аның башында хәзер бер генә уй — ире һәм балалары...

Кайларда йөриләр икән алар, исәннәрме икән, юлдалармы, әллә тотылып, яңадан сөргенгә озатылганнармы? Солтанхәким, ни дисәң дә, әтисе белән, ә менә кызлар япа-ялгыз калдылар бит. Әле ярый Гайшә зиһенле бала, югалып калмас, ни булса да, Мәрзияне ташламас... Инде хәзрәткә генә берәр нәрсә булмасын, ул да яшь түгел бит инде, ничек кичәр ул тауларны? Поездга чыккан булса, инде кайтып җитәрләр иде, ул кайтты бит менә. Димәк, таулар аша җәяү киткәннәр.

Әйтергә генә җиңел — җәяү, ә анда кырык сырт бит, кырык тау, кырык үзән... Бала җитәкләп ничек үтәр ул аларны?

Ә кызлар? Кайда юкка чыкты алар? Поездга утырып киткән булсалар, нигә Уфада очратмады ул аларны? Әллә, куркып яки ялгышып, башка җирдә төшеп калганнармы, әллә, бербер хәл булып, кире кайтып киткәннәрме? Ни булса да, исән генә була күрсеннәр... Исән-сау күрешергә насыйп булсын...

«Раббым, иремне сакла... Раббым, балаларымны сакла...»

Мәһинур абыстайның телендә һәм күңелендә хәзер бары тик шушы дога гына иде...

Шайтан Шакир исә көн дә диярлек Сабираларга бәреп керә башлады. Кайвакытта хәтта инде йокларга әзерләнеп йөргәндә, төнгә каршы да килеп керә. Ул капкада күренү белән, карчыкны ашыга-ашыга түбән өйгә төшерә башлыйлар. Шайтан Шакир чыгып киткәч, интектереп кире менгерәләр. Иң куркынычы — Шайтан Шакирның кыз белән кияү эштә вакытта килеп керүе бар иде, ә карчык үзе генә түбән өйгә төшеп өлгермәскә мөмкин. Артыннан идән капкачын ябарга да кеше кирәк, ә балалар әле кечкенә, үзләре Шайтан Шакирдан куркып качалар...

Шулай бер менеп, бер төшеп интегә торгач, Мәһинур абыстай бөтенләйгә идән астына төшәргә булды. Сабира моңа теше-тырнагы белән каршы булса да, әнисе нык торды. Аның бөтен гаиләне интектерәсе, куркыныч астына куясы килмәде. Һәм Сабира елый-елый ризалашты. Түбән өйгә, абзардан алып кереп, салам җәйделәр, такталардан сәке кебек нәрсә ясап куйдылар. Яктылык һәм һава кереп торсын өчен, нигездәге төннек тишекләрен ачтылар, йомышлары өчен бер почмакка чиләк куйдылар. Сабира үзе яки балалары көнгә берничә тапкыр карчыкка ашарга төшерделәр, төнлә яшереп кенә мунчага алып чыктылар. Бер караганда, болай яшәү тынычрак иде, инде Шайтан Шакирның атылып килеп керүеннән курыкмыйлар, ул ничек керсә, шулай чыгып та китә иде...

Идән астына яңадан бәрәңгеләр салганчы, шулай яшәп карарга булдылар...

Мәһинур абыстай инде ире һәм балаларының кайтып керүләре турында уйларга да курка иде, чөнки Зәйтуганда аларны да нәкъ шушы хәл көтә бит. Авылда тагы берничә кешене шулай бәрәңге бакчаларында, базларда, мунчаларда качып ята, дип сөйлиләр.

Совет власте дин әһелләрен, мулла балаларын, абыстайларны менә шулай караңгы базларга, кара мунчаларга, җир асты куышларына куып керткән иде. Һәм шуларның сөякләре өстендә бәхетле тормыш корырга җыена иде...

* * *

Вакыты тулгач, Гайшәне төрмәдән чыгарып җибәрделәр...

Ул иң башта комендатурага барып теркәлергә, яңадан сөрген исемлегенә кертелергә тиеш иде. Аннан соң Гайшә туптуры үзләре яшәгән баракка китте, аның тизрәк сеңлесе Мәрзияне күрәсе килде. Әмма баракта бөтенләй чит кешеләр яши булып чыкты, ә Мәрзияне анда күрүче дә, белүче дә юк иде. Бу хәбәрдән Гайшәнең коты чыкты, ул бит әле сеңлесен баракта, татарлар янында дип уйлый иде. Ә баракта ул белгән кешеләрдән беркем калмаган, кайсы үлгән, кайсы качкан, кайсы төрмәдә утыра булып чыкты...

Гайшә бaрактан урамга чыкты, дала җиле аның күзләренә кызыл ком китереп бәрде. Ул теш араларына кереп шыгырдады, аяк атларга ирек бирмәде, ачу белән Гайшәнең сәләмә киемнәрен йолыкты. Гайшә исә, бaрактан баракка кереп, сеңлесен эзли башлады, әмма бер җирдә дә аны таба алмады, Мәрзияне белүчеләр дә юк иде. Чөнки тоткыннар гел алышынып тора, узган ел килгәннәрнең күбесе бу җәйдә тифтан кырылып беткән, алар урынына инде яңаларын китереп тутырганнар. Меңләгән бaрактан, йөз меңләгән кеше арасыннан бер бала кешене эзләү — даладан энә эзләү белән бер иде. Әмма Гайшә барыбер өметен өзмәде. Һәм сеңлесе Мәрзияне тапмыйча ул барыбер туктамаячак иде...

Ул арып бистә читендәге калкулыкка килеп утырды...

Ары таба җир асты шәһәрлеге — землянкалар башланып китә иде...

Ул, дистә чакрымнарга сузылып, Урал елгасына хәтле төшеп җиткән, кабер кебек калкулыклардан чамалап кына аның астында кешеләр яшәгәнен белергә була иде.

«Бәлки, Мәрзия шушы куышларның берсендә яшидер? — дип уйлады Гайшә, сәер шәһәрлеккә карап. — Анда татарларны күп, диделәр бит, качканнарны яңадан баракларга кертмәгәннәр, җир астына куганнар. Бәлки әле, Самат та шундадыр...»

Самат турында уйлауга, Гайшәнең битенә ут капты...

Зәңгәр күзле бу егет аның бөтен күңелен биләп бара иде...

Гайшә бу караңгы сөрген дөньясында ике яктылыгы, өмет нуры барлыгын белә, аның берсе — сеңлесе Мәрзия, икенчесе Самат иде. Һәм ул бер очрамаса, бер очрарга тиеш иде, Магнитка, нәрсә әйтсәң дә, Мәскәү түгел бит, тере кешене монда барыбер эзләп табарга була иде.

Ул төнне Гайшә баракта бер татар гаиләсе янында кунды...

Икенче көнне якшәмбе иде, ул тагы элек үзләре яшәгән барак ягына таба китте, нигәдер сеңлесен гел шунда табар кебек тоелды. Ә анда аны Самат көтеп тора иде...

Самат бу баракка гел килеп йөри, Гайшәнең төрмәдән кайтып керүен көтә. Кичә исә ул бирегә иртәрәк килеп киткән, алар Гайшә белән аймыл булганнар иде. Күңеле нидер сизенеп, бүген ул тагы килеп җиткән һәм Гайшәне көтеп тора иде. Аны күргәч, Гайшә уңайсызланып китте. Үзенең өстендәге сәләмә киемнәрдән дә, ертык чабатасыннан да оялды ул. Ә Самат сөрген өчен яхшы киенгән, ул төрмәдә үлеп яткан егет түгел, өс-башы да, үзе дә матур һәм җыйнак иде. Гайшә аның белән ничек сүз башларга белмәде, әле ярый Самат үзе ярдәмгә килде:

— Син Мәрзияне эзлисеңме, Гайшә? — диде ул, аны тизрәк сөендерәсе килеп.

— Әйе, Самат, син аның турында берәр нәрсә беләсеңме әллә?

— Мәрзия безнең белән тора, землянкада... Һәр көн саен сине көтә... Әнә Урал суы буенда безнең куышлар.

— Чынлапмы, Самат? Мәрзия исәнме? Ул сезнең беләнме?

Гайшә шулай диде дә шатлыгыннан елап та җибәрде.

Сеңлесе исән иде! Ул Саматлар белән бергә яши! Менә бит нинди бәхет, менә бит нинди шатлык. Калган барысына да түзәргә була, бөтен авырлыкларны да онытырга була, азакта кадерле кешеләрең белән очрашу көтсә...

Саматның аны кулларыннан алып юатасы килде, әмма ул Гайшәгә кагылырга оялды. Шушы сәләмә киемнәреннән дә Гайшә аңа хан кызыннан да затлы булып күренә иде, ялгыш орынып, хәтерен калдырырмын дип курыкты.

— Әйдә, безгә киттек, Гайшә. Сине барыбыз да көтәбез. Мәрзия дә, бабай да, сеңелләр дә. Мин үзем дә бик көттем сине...

Гайшә, озын керфекләрен сирпеп, аңа карап алды. Егет мөлдерәп кызга карап тора иде, аның җавабына хәзер Саматның бөтен гомере бәйләнгән иде...

— Кайтыйк алайса, Самат, — диде кыз тыйнак кына.

«Киттек» димәде, «кайтыйк» диде, әйтерсең лә ул Самат белән үз өенә, үз куышына кайта иде. Һәм бу, чыннан да, шулай иде.

Яшьләр, куанып сөйләшә-сөйләшә, бистә читендәге землянкаларга таба атладылар. Каткан балчык арасында сөртенеп егылмас өчен, Самат Гайшәнең беләгеннән тотып алды. Әллә дала җиленнән, әллә дулкынланудан, кызның арык тәне дер-дер калтырый иде. Аңа Самат белән шулай җитәкләшеп баруы бик рәхәт иде, ул янында үзен якларга һәм сакларга әзер торган кеше барлыгын тойды. Шул тотудан Самат инде аны башка ычкындырмады. Шушылай ак беләкләреннән алып, ул Гайшәне бистә читенә хәтле генә түгел, җир читенә кадәр дә җитәкләп барырга әзер иде...

Җир астына төшкәч тә, башта Гайшәнең күзләре караңгыга ияләшмичә торды. Аннан ул идән уртасындагы мичне күреп алды, аның яктысы бөтен куышка тарала иде. Мич тирәсенә бала-чага җыелган, чаршау артында да кемдер бар, мөгаен, Аллаһъяр бабайдыр. Алар кергәч, мич тирәсендәгеләр сикерешеп тордылар, берсе, атылып, Гайшәгә килеп сарылды. Бу кыз бала Мәрзия иде, ул шушы бер җәйдә шактый үсеп, олыгаеп киткән, урамда күрсәң, танырлык та түгел. Аннан күрә башка балалар да Гайшәгә килеп сарылдылар, алар аны барысы да барак буенча таныйлар иде. Балалар белән мәш килгән арада, чаршау артыннан Аллаһъяр бабай да чыкты, ул Гайшәне үз баласы кебек каршы алды. Гайшә белән бергә җир астына нур кергән иде, өмет, шатлык, яңа тормыш үзе килеп кергән иде...

Җир астындагы шатлыкның иге-чиге булмады, әйтерсең лә төрмәдән Гайшә кайтмаган, ә күктән фәрештә иңгән. Алар аны барысы да шулай кабул итте. Самат белән сеңлесе Маһия тиз-тиз генә табын әзерли башладылар, нигъмәттә ни бар, барысын да өстәлгә чыгардылар. Ике гаилә, бер булып, шушы зур бәхеткә куанып, табын янына утырдылар. Җир асты куышы кешеләрнең күңел нуры, җан җылысы, сагынылган бәхетләре белән тулды. Гайшә белән Самат шуның нурларында коеналар иде. Бүген бөтен дөнья, җир асты һәм җир өсте патшалыгы шушы икәү тирәсендә әйләнә, аларга хезмәт итә иде...

Гайшәгә бу җир асты йорты бик ошады...

Ул бик җыйнак, чиста һәм җылы иде. Иң мөһиме — ул башкалардан аерым, үзләренә генә иде. Монда беркем кереп өйрәтеп йөрми, шәхси тормышыңа катнашмый, үз яшәү рәвешен көчләп такмый. Дөрес, ярдәм итүче дә юк, син бу җир астын нәрсә ягып җылытасың, анда нәрсә ашап торасың — беркемнең эше юк. Барысы өчен бер Маһия эшләгән, хәзер әле ярый Самат та кайтып тотынган. Алар Мәрзияне иң авыр вакытта үзләренә сыендырганнар, үз туганнары кебек караганнар, Гайшә моны беркайчан да онытмаячак. Хәзер алга таба аларның үзләренә торыр җир эзләргә кала инде, сеңлесе белән икәүләшеп аларны кысрыклап яшәп булмас. Саматтан да ояла Гайшә.

Тик Аллаһъяр картның бу яшьләргә карата үз фикерније бар булып чыкты. Ул аларны озакка сузмыйча никахландырырга, өйләндерергә уйлый иде. Башта ул бу хакта ипләп кенә оныгы Самат белән сөйләшеп карады:

— Безнең динебез буенча, буй җиткән кыз бала чит ир-ат белән янәшә яши алмый, улым, — диде ул, Гайшә чыгып киткән арада. — Ә Гайшәнең башка барыр урыны юк, ул яшәргә монда калыр инде, иншаллаһ. Яшегез дә җиткән, кызы да

бик әйбәт, әллә, дим, кавышасызмы, улым? Гаилә корасызмы, диюем... Мин дә бу дөньяда озак тормам инде, үзем исән вакытта сине башлы-күзле итеп каласым килә иде...

— Ул риза булырмы икән соң? — диде Самат уңайсызланып.

Кинәт кенә аның бөтен тәнен ялкын чорнап алды, әмма ул пешерә торган ут түгел, яшь җанның кайнарлыгы иде. Бабасы аның иң зур хыялын әйтте дә бирде бит, рәхмәт яугыры. Әле Самат үзе бу хакта авыз ачарга оялыр иде, һаман сузып йөртер иде. Ул Гайшәне инде күптән, баракта яшәгәндә үк ошатып йөри иде. Әмма алар анда хайваннан да түбән дәрәҗәдә яшәделәр, ничек шундый шартларда сөюеңне белдерәсең. Гайшә аны төрмәдә үлемнән коткаргач, Самат аңа фәрештәгә караган кебек карый башлады. Мәрзиянең монда яшәве Самат күңелендә тагы өмет уятты, чөнки Гайшә барыбер сеңлесе янына киләчәк иде. Һәм шулай булды да.

— Ә син әйтеп кара, улым, оялма, — диде Аллаһъяр карт, оныгының уйларын сизгәндәй. — Кыз бала үзе башламас бу сүзне, бәлки, ул синең әйткәнне көтеп йөридер. Синдә күңеле бар кебек аның, тәвәккәллә, улым...

Һәм Самат тәвәккәлләп карарга булды...

Икенче көнне кичке якта алар Урал суы буена төшеп киттеләр...

Көн бик матур иде, әле җәй үтмәгән, әмма инде көз сулышы да сизелә...

Еракта, Урал елгасы аръягында, урманнарга инде ялкын кабып килә — алар, әллә шәфәкъ яктысыннан, әллә иртә көздән, кып-кызыл булып янып утыралар. Араларында яшел карагай-чыршылар каралып тора, каеннар исә сарыдан киенгән. Уралда барысы да кинәт башлана шул — җәй үтеп бетми, көз башлана, көзнең артына бастырып салкын кыш килә. Әмма хәзер әле кышка иртә, даланы җәйнең җылы кояшы яктырта. Бары тик җиләс җил генә җәйнең үтеп баруын сиздерә, алда көзләр торганын искәртә.

Алар җитәкләшеп Урал суы буенда йөрделәр...

Үлем төрмәләреннән, бараклардан, җир асты куышларыннан соң күңел яктылыкка, матурлыкка сусаган иде. Һәм дөнья бүген аларга, чыннан да, бик матур булып күренде. Бигрәк тә табигать, елга аша күренеп торган Урал таулары, зәңгәр күк һәм иксез-чиксез дала. Бүген барысы да Самат белән Гайшә өчен генә яши кебек иде, әйтерсең лә аларның җанын иркәләр өчен генә табигать шундый алтын нурларга төренгән. Һәм бар табигать, тын калып, егетнең кыз балага карата булган олы мәхәббәт сүзләрен әйтүен көтә иде...

Самат сак кына кызның ябык кулларын учларына алды...
Алар ут кебек кайнар иде...
Самат бу дөньяда иң җитди, иң кирәкле сүзен әйтергә җыена иде.
— Әйдә, бергә булыйк, Гайшә, — диде Самат, кызның кулларын кысып тотып. — Мин сине күптән яратып йөрим инде, бу хакта әйтә генә алмадым... Язмыш үзе булышты... Чык миңа кияүгә, Гайшә, рәнҗетмәм, фәрештәм итеп карармын. Син, чыннан да, минем өчен изге фәрештә, хан кызы... Кулымнан килсә, мин сине җир астында түгел, хан сарайларында яшәтер идем... Алла теләсә, анысы да булыр әле, Гайшә, сабыр итик...
Бу сүзләрдән Гайшәнең күңеле тулды, башы әйләнеп китте. Бу мизгелләрдә ул үзенең язмышы хәл ителгәнен сизде:
— Син яхшы кеше, Самат, — диде ул, егеткә туры карарга оялып. — Мин дә сиңа күптән игътибар итеп йөрим...
Кыз «ошатып йөрим» дип әйтергә оялды...
— Тик менә әти-әнинең янда булмавы борчый, — дип дәвам итте ул. — Аларның фатихасын алмыйча дөрес булырмы?
— Аллаһъяр бабай дөрес булыр, диде. Минекеләр дә юк бит, хәзер нишлисең инде? Бабай үзе никах укыр... Сеңелләрне дә бергә үстерербез... Дөньялар гел болай бармас әле, Гайшә, бер җир өстенә дә чыгарбыз, Алла теләсә... Ризалыгыңны бир, җаным?
Егет бу сүзләрне шулхәтле өзелеп әйтте, аның саф хисләреннән аяк астындагы таш та эрер, тимер йомшарыр иде.
— Мин риза, Самат, — диде Гайшә, аның күзләренә туры карап. — Аллаһы Тәгаләдән шулай язгандыр. Бергә-бергә җиңелрәк булыр, иншаллаһ. Әмма нинди шартларда да динне онытмаска сүз бир, Самат...
— И бәгърем, мин үзем дә мулла баласы бит, — диде Самат, аның бу сүзләренә куанып. — Мин төрмәдә дә төннәрен, яткан җирдән булса да, намаз укып ята идем. Балаларыбыз да шушы юлда булыр, иншаллаһ...
Шулай итеп, иң җитди сүзләр әйтелде, вәгъдәләр бирешелде, никах мәсьәләсе хәл ителде. Бу яңалыкны хәбәр итәргә алар ашыгып җир асты куышына кайтып киттеләр. Алар, бик теләсәләр дә, чәнечкеле тимерчыбыкның теге ягына чыга алмыйлар, үз тормышларын, үз бәхетләрен шушы кысада гына корырга тиешләр иде...
Алар җитәкләшеп Урал ярына күтәрелделәр...
Аларга каршы буш далада таш шәһәр күтәрелеп килә иде.
Меңәрләгән кеше тифтан, ачлыктан кырылса да, сөргенгә сөрелгән халыкның яртысыннан күбе үлеп барса да, яңа шә-

һәр һәм металлургия комбинаты күзгә күренеп күтәрелә. Чөнки илдә халык бетмәгән, бигрәк тә авылларда... Берсе үлсә, йөзне китереп тыгалар. Чөнки бөек төзелешне туктатырга, өзәргә ярамый...

Кичке як булса да, бередә эш туктап тормый...

Монда сменалап көне-төне эшлиләр...

Чөнки илгә чуен кирәк!

Чуен кирәк!

Чуен кирәк!

Котырып корал ясау өчен чуен кирәк...

Ул чуенны көне-төне коярга чуен кебек чыдам кешеләр кирәк...

Ирексез коллардан советлар өчен яңа кадрлар ясыйлар...

Әнә алар, мәңгелектән торган Әтәч тавын актарып, мәгъдән — тимер рудасы чыгаралар. Әнә алар, болытларга җиткереп, мартен мичләре төзиләр. Буш даланы кишәрләргә бүлеп, урам-урам шәһәр төзеп киләләр. Дөрес, бу шәһәрне төзегән татарлар үзләре әле тагы ярты гасыр баракларда һәм агач алачыкларда калачаклар. Әмма барыбер киләчәк өчен төзиләр. Аларга шулай кушылган...

Совет иле бу колларны рухи яктан яңадан тәрбияләү турында да кайгырта...

Гайшә белән Самат өйләнешкән елны, бөтен Уралда беренчеләрдән булып, бередә тавышлы кинотеатр ачылыр, аңа «Магнитка» дип исем бирерләр.

Бу фильмнар белән сөргенгә сөрелгән авыл татарларыннан совет патриотлары әзерләргә тырышырлар...

Ил өчен бушка эшли торган, ил өчен утка керә торган, ил өчен егылып үлә торган чуен кешеләр. Һәм шушы көздә үк яшь шәһәрдә педагогия институты һәм тау-металлургия институты ачылыр. Чөнки илгә белемле кадрлар кирәк, америкаи һәм немец инженерларын куып җибәргәннән соң, бу тимер гигантын эшләтә алырлык яңа белгечләр кирәк. Әмма бу уку йортларына озак еллар буе колларның балаларын алмаслар, чөнки алар да, әти-әниләре кебек, хокуксызлар булып исәпләнерләр.

Әмма хокуксызлар үзләре бу хакта уйламыйлар.

Әнә алар бүген, туган якларындагы кебек, җир асты алачыгына качып, никах мәҗлесе үткәреп яталар...

Бүген ике татар баласы — Самат белән Гайшә өйләнешәләр. Никах мәҗлесенә исән калган муллалар чакырылган, үзләре белеп-ишетеп килгән татарлар да шактый. Татар гадәте буенча, һәркем үзе белән нәрсә дә булса кыстырып алып килгән, яшьләрнең гомерләрендә бер була торган мәҗлесне истә калырлык итеп уздырырга тырышканнар. Әллә кайларда могҗиза белән сакланып калган каклаган казлар,

туган як җиләкләреннән киптереп килгән каклар, шикәрдән булса да пешереп әзерләнгән чәкчәкләр, бавырсак-коймаклар барысы да табынга чыгып утырды. Яшьләрнең бернәрсәсез тормыш башлаганнарын белеп, якташлары аларга кем бер төргәк ситсы, кем урын җаймәсе, кем хәтта мендәргә хәтле күтәреп килгән. Боларына Гайшә бигрәк тә куанды, чөнки җир астында булса да, чаршау корып булса да, аның Самат белән үз почмагын булдырасы килә иде. Самат инде анда агачтан сәке дә ясап куйган иде...

Бүген аларның җир асты куышлары бигрәк тә матур булып күренә...

Кыз балалар көне буе аны бизәделәр, Урал суы буеннан карагай ботаклары, соңгы чәчәкләрне җыеп менделәр, аларны үзләренчә кырый-кырыйга тезеп чыктылар. Җир идәнгә мул итеп сары яфраклар сиптеләр. Җир астын якты лампалар белән яктырттылар. Бөтен җир ялт итеп көлеп тора иде. Сөргенгә сөрелгән, җир асларына куып кертелгән адәм балалары хәтта монда да матурлык тудырырга, дөнья яме табарга тырышалар иде...

Самат белән Гайшәгә никахны Аллаһъяр бабай үзе укыды...

Күкләрдә язып куелган тәкъдир җир астында теркәлде...

Җир һәм күкләр алдында Самат белән Гайшә ир белән хатын дип игълан ителде...

Никах укылып, ашап-эчкәннән соң, картлар сулыш алырга өскә чыктылар...

Җир астына яшьләр хуҗа булып калды...

Шуны гына көткәндәй, татар яшьләре ду килеп уйный, күңел ача башладылар. Күрше ббарактан кергән татар егете әллә каян гына гармунын тартып чыгарды һәм өздереп уйнап җибәрде. Җир астында Арча, Шөгер, Саба якларының моңлы, дәртле көйләре яңгырады, әйтерсең лә бу никах туе Зәй, Мишә буйларында бара иде. Уйнаучысы — Бөгелмә вокзалында гармунын алдырган татар егете. Шул гармуны аркасында ул соңыннан акылын да җуя язды, берара җиңеләеп йөрде. Соңыннан төзелештә көне-төне эшләп, ипи карточкасын акчага алыштырып, ул Магнитка базарыннан шундый ук тальян сатып алды. Хәзер татарларның бер генә мәҗлесе дә аның тальяныннан башка узмый, ул кайда да үзенең «Асылъяр» көен уйнамыйча калмый. Егетнең чын исемен беркем дә белми, аны хәзер алдында да, артында да Асылъяр дип йөртәләр. Менә ул хәзер дә, башын гармунына кырын салып, шушы көйне өздереп уйнап җибәрде. Егет үзе уйный, үзе җырлый, әллә тир бөртекләре, әллә күз яшьләре тамчы-тамчы булып гармун күкрәгенә тама.

Әйдә барыйк сахраларга, сахраларга,
Гөлләр араларына, Асылъяр.
Матур яр, гүзәлем,
Өзелә бит үзәгем.
Безнең хәзер тиң чагыбыз, тиң чагыбыз
Былбыл балаларына, Асылъяр.
Асылъяр, күгәрчен,
Күрми ничек түзәрсең...

Гармунчы егет, күз яшьләрен күрсәтмәс өчен, башын гармун өстенә салды, үксүен ишетмәсеннәр өчен, каты итеп күрекләрен кычкыртып алды. Әйтерсең лә гармун күрекләрен түгел, яшьли телгәләнеп беткән үз йөрәген, үз язмышын шулай ачыргаланып тарта иде...

Яшьлек безнең багыбыз, багыбыз,
Гөлләр өзәр чагыбыз, Асылъяр.
Матур яр, кошкаем,
Аерылабыз, дускаем.
Бакчадагы гөлләр кебек, гөлләр кебек
Гөрләп үсәр чагыбыз, матур яр.
Асылъяр, кошкаем,
Аерылмыйк, дускаем.
Асылъяр, кенәри,
Бергә булырбыз әле...

Җырның соңгы сүзләрен җир астындагы яшьләр дә күтәреп алдылар.

Гайшә белән Самат, бер-берләренең җилкәләренә башларын салып, әкрен генә аларга кушылдылар...

Асылъяр, кошкаем,
Аерылмыйк, дускаем...

Җир астыннан ургылып чыккан татар моңы өстә басып торучы картларга да килеп ишетелде...

Аларның җан авазы булып Урал артындагы туган якларына китте...

Урал артында кызарып кояш баеп килә иде. Туган якларга кара төн килә. Әмма төн ничек кенә озын булмасын, барыбер таң атачак, кояш чыгачак иде. Тормыш дәвам итәчәк. Менә шушы яшьләрдә, аларның балаларында, нәселендә дәвам итәчәк татар тормышы. Хәзергә алар җир асларына куып кертелгән, әмма барыбер бер өскә чыгачак алар, иншаллаһ, чыгачак. Ил картлары моңа чын күңелдән ышаналар һәм гомер кояшлары баеп барган мизгелдә дөньяны яшьләр кулына калдырып китәләр.

Җир астында сөргендәге татарларның туе бара...

* * *

Асылгәрәй картның күптән болай тынычлап йоклаганы юк иде...

Тамагы тук, урыны коры, эчәргә су баскан саен. Аяк очында бөгәрләнеп Сарбай ята, ул бу тирәгә беркемне якын җибәрми, очкан кошларга да колакларын тырпайта. Асылгәрәй карт бу кыргый этнең үзенә ни дәрәҗәдә кирәклеген, ярдәмче буласын хәзер бигрәк тә яхшы аңлады. Ул, хайван булса да, чын мәгънәсендә юлдаш иде. Инде арт тәпиенә дә нык басып килә, теге көнне селәүсен талаган йоннары да тигезләнгән. Кыскасы, алар икесе дә бу таулар тормышына инде ияләнеп баралар. Хәзер аларга әкрен генә атларга да атларга инде. Тәмам теге якка чыгып җиткәнче. Ә Урал аръягында инде үзәнлекләр, анда җиңелрәк булачак, иншаллаһ!

— Кузгалдык булмаса, Сарбай, — диде карт, юлдашы белән киңәш иткәндәй. — Безгә бит әле күп юл үтәргә кирәк... Аллага тапшырдык, туган...

Урман араларыннан, үзәнлекләрдән, тарлавыклардан туры юл эзләп, башта Асылгәрәй карт алдан барды. Әмма ул тиз арыды, еш-еш туктап, ял итә башлады. Моны күреп, Сарбай йөгереп алга чыкты. Интекмә, минем арттан гына бар инде дигәндәй, Асылгәрәй картка борылып-борылып карады. Әйтерсең лә эт картка ни кирәген белә иде. Һәм ул, үзе генә белгән җәнлек сукмаклары буйлап, каршыдагы сыртка менеп китте. Кыргый эт җайлы юллар табарга тырышты, адәм баласы йөри алмаслык кыя-ташлы урыннарны әйләнеп үтте, тар тарлавыклар буенча алга чапты. Асылгәрәй картка аның артыннан ияреп барырга гына калды. Арыганда туктап ял иттеләр, чишмә суы эчтеләр, һәркайсы ашарга үзе эзләп тапты. Сарбай өчен бу җирдә кыймылдаган һәрнәрсә булса, карт анда-санда күренә башлаган җиләкләрне өзгәләп, кайда балык тотып, кайда үлән ашап, юлларын дәвам иттеләр.

Шулай итеп, эшне җайга салдылар.

Эт — алдан, карт арттан барды, инде әллә ничә тау сыртын тыныч кына үттеләр, инде әллә ничә төн кундылар. Әмма карт сизенде — барыр юллары әле шактый иде. Тау сыртларының да очы-кырые күренми, әйтерсең лә алар җир астыннан үсеп чыгалар. Үсеп чыгалар да, әкияттәге дию пәриләре кебек, картның каршына килеп басалар. Ничек тә аны аргы якка уздырмас өчен тырышалар. Карт инде үзе дә арый башлады, ачыкты, талчыкты, әмма аның алга атламый башка чарасы юк иде.

Ничә көн үтеп, юлында бер адәм заты очрамаганга ул инде аптырый башлады. Монда авыллар да күренми, кешеләр дә яшәми, ахры. Баштарак ул аларның очрамавына сө-

енгән генә иде, әмма тора-бара хафалана башлады. Авыллар булса, ичмасам, ашарына бераз сорап алыр иде, кешечә туктап ял итәр иде. Юлны чамалар иде. Хәзергә ул бары тик кояшка карап кына бара, кояш баешына таба бара...

Асылгәрәй карт дөрес сизенә — ул әле юлның яртысында гына иде...

Алда әле берсеннән-берсе биек, берсеннән-берсе дәһшәтле Баштау сыртлары, Шайтан, Караташ таулары, аннан Юрматау сыртлары, Баштын, Акборын таулары, барыр юлга аркылы сузылып яткан Алатау, Олытау, Кыл сыртлары, Баграж, Биктәр, Фатыйматаш, Мендем, Шүлгән таулары. Алда әле Агыйдел елгасы. Карт кая гына борылса да, шушы мәңгелек таулар һәм бөек елга аның каршына чыгып басачаклар, юлына аркылы төшәчәкләр. Илгә кайтып җитү өчен шуларның барысын да кичәргә, үтәргә кирәк иде...

Инде җәй уртасы да килеп җитте...

Тау битләрендә күзгә күренеп җиләкләр өлгерде, шомырт еште, чикләвекләр тулыша башлады. Бу нигъмәт Асылгәрәй картка бик тә ярап куйды, чөнки соңгы вакытта ул коры үләнгә генә калып бара иде. Сарбай берничә тапкыр кошмазар тотып килсә дә, карт аны ашый алмады, бу ризыкны үләксә итеп кабул итте. Эткә яраган кешегә ярап бетми иде шул. Әле ярый суда балык бар, җирдә үлән үсә. Әмма авыллар да, кешеләр дә һаман очрамый, тирә-якта урман һәм таулардан кала берни юк иде...

Менә берзаман таулар да бетеп киткән кебек тоелды, каршыда киң үзәнлекләр ачылып китте. Сарбай, тәгәрәп диярлек, тигез җирдән чаба башлады. Карт үзе дә тау-таштан бик арыган иде, үләнле йомшак җир буйлап рәхәтләнеп атлап китте. Тигез җирнең үзенә күрә бер матурлыгы бар шул, ул, таулар кебек, җанны кысмый. Күз карашың да, атлаган саен, салкын ташка килеп төртелми, тоташ яшеллек диңгезендә йөзә. Юлда урыны-урыны белән куаклыклар, урманнар очрап куя, әмма бу тау урманнары түгел, тигез җирдә таралып үскән агачлар. Асылгәрәй картның үзе кебек, аның ишле нәселе, кавеме кебек, җирне тотып торалар. Идел-Кама буйларында зур таулар юк бит, татар халкы киң үзәннәргә таралып китеп, җәелеп яши. Анда бөтен җирдә кырлар, үзәнлекләр, болынлыклар. Дөньяның җәннәт кебек җирләре. Бигрәк тә буш, ач далалардан соң, үзәккә үткән бу кыя-таулардан соң, туган җире Асылгәрәй картка җәннәт булып тоела иде...

Алда кинәт кенә Сарбайның буыла-буыла ярсып өргәне ишетелде. Ул хәтта улап-улап куя, чинап елый иде.

Асылгәрәй карт куркып куйды, чөнки Сарбай юкка болай өрмәс. Бер-бер хәл булса гына ул шулай ярсырга мөм-

кин. Карт адымнарын тизләтә төште һәм урман эчендәге аланлыкка килеп чыкты. Аланны урталай ярып киң елга агып ята иде, мөгаен, Агыйдел үзедер, чөнки картның юлында әле мондый зур елга очрамады. Елга ярында исә берничә ир-ат кайнаша, берсе, мылтыгын Сарбайга төбәп, атып җибәрергә әзерләнгән иде...

— Тукта, атма! — дип кычкырып җибәрде Асылгәрәй карт, йөгереп килә-килешкә. — Атасы булма, хуҗалы эт бит ул!

— Эт түгел, бүре бит ул, карт тиле! — дип акырды аңа каршы мылтыклы ир. — Кит, югыйсә икегезне берьюлы бетерәм!

Асылгәрәй карт аны тыңлап тормады, атылып Сарбай өстенә ташланды, алар икесе бергә яр астына тәгәрәп төштеләр. Аларга төбәлгән пуля сызгырып баш очыннан очып үтте. Моны күреп, астагы ирләр шаркылдашып көлешә башладылар. Алар учак тирәсендә нидер пешереп маташалар иде...

«Кемнәр булыр икән болар? — дип уйлады карт, кочагындагы Сарбайны көчкә тыеп. — Татар дисәң, татарга охшамаганнар, телләре дә башкарак, йөзләре дә безнеке кебек түгел... Күз урынында кара сызык кына, йөз дә кап-кара... Җәй көне булуга карамастан, башларында җонлы бүрек... Кыланышлары буенча юньле кешеләргә охшамаган болар, әллә нинди юлбасарларга охшаганнар... Инде, Раббым, боларның зыяныннан үзең сакла...»

Ул арада җонлы башлар карт тирәсенә җыела башладылар. Алардан аракы исе бөркелеп тора иде. Бу бәндәләр яр буенда учак ягып, ит кыздырып, аракы эчеп яталар икән, карт нәкъ шуларның өсләренә килеп чыккан. Инде хәзер болардан исән-сау котылырга кирәк иде...

— Бүреңне ычкындырма, югыйсә икегезне дә атып егам, — диде кара-чутыр, мылтыгына күрсәтеп.

— Эт ул, минем эт, беркемгә дә тими, — диде карт, мөмкин кадәр тыныч булырга тырышып. — Шулай бит, Сарбай?

Сарбай юеш борынын картның җилкәсенә төртеп үксеп-улап куйды...

Аның бу шомлы тавышыннан кара-чутыр тагы мылтыгына ябышты. Моны күреп, Сарбай Асылгәрәй картның артына барып ятты. Ул, бер сикерсә, бу җонлы башның бугазын чәйнәп өзә ала иде, әмма хуҗасына зыян тиюе бар, чөнки тегеләр күп. Бу кешеләрнең явыз бәндәләр икәнлеген ул инде аңлаган иде. Аларга моннан тизрәк китәргә кирәк. Һәм ул тын гына хуҗасының әмерен көтә башлады...

— Сүзләрегез аңлашылса да, үзегез татарлар түгел, ахры, — дип сүз башлады Асылгәрәй карт. — Бу нинди зур су була соң, Агыйдел үзе түгелдер бит?

Аның бу сүзләреннән исерек ирләр нигәдер тәгәрәшеп көлә башладылар. Йөзен сакал-мыек баскан бу карт кай тирәдә йөрүен дә белми икән әле. Хәзер тиле белән урман тулган, барысы да дала ягыннан, төзелештән килә. Бу да шуннан качкан сукбайга охшаган...

— Татарлар түгел, бүрзәннәр без, — диде җонлы баш, көлеп туйгач. — Ә бу безнең баш елгабыз — Агыйдел була... Ишеткәнең бар идеме?

— Бар, бар, — дигән булды карт, аларны тынычландыру өчен. — Бездә дә Идел суы бар бит...

— Идел берәү генә була, шулай бит, егетләр?

Егетләр дигәннәре һау-һаулап җавап бирделәр...

Аннан тагы, картны онытып, сыйланырга тотындылар. Кара-чутыр, йомшарып китеп, картка да пешкән ит кисәкләре ыргытты, стаканы белән аракы төртте. Асылгәрәй карт ашыгып баш тартты, бер читкәрәк барып утырды...

— Нигә биргәндә ашамыйсың, тамагың шулчаклы тукмыни? — дип төксе генә сорап куйды җонлы баш. — Биргәндә эчеп тә куй, урманда моның ишене тапмассың...

— Мөселман кешесе мин, безгә болар харам, — диде Асылгәрәй карт, бер читкә карап.

Аның бу исерек юлбасарлар яныннан тизрәк торып китәсе килә иде...

Әмма аларның ни эшлиселәрен белеп булмый, арттан атып үтерүләре дә бар... Әнә Сарбайны ике дә уйламыйча атарга әзерләнеп яталар иде бит... Болардан мәрхәмәт көтеп булмас, ничек тә моннан исән-имин китәргә кирәк. Ничек тә аргы ярга чыгарга кирәк. Ә ничек — монысын карт әле үзе дә белми иде...

— Ә безнең динебез буенча ярый, — дип кешнәде җонлы баш. — Безнең үз аллаларыбыз бар, алар безгә рөхсәт итә. Чөнки без аларга да өлеш чыгарабыз. Менә карап тор.

Җонлы баш шулай диде дә, сөяк алып, учакка томырды...

— Менә монысы ут иясенә, — диде ул, шаркылдап көлеп.

Аннан бер ит кисәген суга, берсен урман эченә томырды, җиргә бәрде...

— Болары су иясенә, җир ияләренә...

Карт үз каршында кыргый мәҗүсиләр утыруын аңлап алды...

Болар атлы сакчылардан да куркынычрак иде, чөнки болар үз илаһәләренә теләсә нәрсәне, хәтта кешене дә корбанга китерергә мөмкиннәр. Кара урманда, таулар арасында шундый кыргый кешеләр яшәгәнен ишеткәне бар иде Асылгәрәй картның, әмма моңа ышанып бетми иде. Менә хәзер үз күзләре белән күрде инде.

— Аллаһы Тәгалә бер генә була, ыланнар, — диде Асыл-

гәрәй карт, аларга хакыйкатьне җиткерергә уйлап. — Бу җир-суларның, ут-тауларның үзләрен дә Аллаһ барлыкка китергән бит, шуңа күрә дә гыйбадәт кылу бары тик аңа гына булырга тиеш. Корбан да Аллаһ ризалыгы өчен генә бирелә...

Әмма учак янындагылар аны тыңламадылар да. Алар, кыргый этләр кебек ырлашып, кулларындагы ит кисәкләрен кимерәләр иде. Юк, эттән дә яман кыланалар болар. Сарбай да үзенә күрә бер тәртип белән яши, кайда нәрсә ярамаганын белә. Боларга исә сүз дә керми, яхшы үрнәк тә кирәкми. Явызланган кыргыйлар эттән дә яман була икән...

Шул уйлар белән Асылгәрәй карт Агыйдел буена төште...

Зур суда бит-кулларын юды, яхшылап тәһарәтен алды...

Аннан кыйбланы турылап, намазга басты. Бу бәндәләрдән исән-имин хәлдә котылуны сорап, ул Аллаһтан ялварды, дога кылды. Исерек төркем астан гына аның һәр хәрәкәтен күзәтте. Аларга очраган кешеләрнең исән-сау котылганнары юк иде әле, шуңа күрә дә алар бу татар картын күздән ычкындырмадылар. Кешенең түгел, этнең дә качып котылганы юк алардан. Моны Сарбай да сизенә, шуңа күрә алардан ерак булырга тырыша, гел Асылгәрәй карт янында бөтерелә...

— Йә, картлач, догаңны кылдыңмы? — диде кара-чутыр, кырын яткан җирдән картка карап. — Хәзер тикшереп карыйбыз — синең Аллаң җиңәрме, безнекеме? Бас шунда! Әнә шул каенга сөялеп бас...

Ул чайкала-чайкала урыныннан торды, мылтыгын сөйрәп, Асылгәрәй картка таба килә башлады. Моны күреп, Сарбай шомлы ырлап куйды, эт булып эт хәвеф якынлашканын сизә иде...

Шунда карт бу бәндәнең маңгаенда ут белән кыздырып сугылган тамганы күрде. Башта ул эсселе-суыклы булып китте, чөнки заман ахырында чыккан Дәҗҗалның маңгаенда тамга буласын, аны мөселманнар гына күрә аласын белә иде ул. Дәҗҗал маңгаенда «кяфер» дигән сүз язылган булачак, ә бу бәндәнең «бур» дигән сүз ярылып ята. Элек, патша заманында, кеше үтерүчеләргә, каракларга шундый тамга салалар иде. Димәк, ул заманда ук бу кеше шундыйлар рәтендә булган. Аның маңгаендагы тамгасы кып-кызыл булып җөйләнеп тора, әйтерсең лә мөгез чыгып килә.

Бурның мылтык тотып үзенә таба килүен күреп, карт сискәнеп китте...

Тукта, әллә аны атып үтермәкче буламы соң бу бәндә? Нигә мылтыгын төзи ул аңа таба? Нигә аны башкалары туктатмый, кеше хәтле кешенең җанын шулай җиңел генә кыярга мөмкинме?!

— Тукта, син нишләргә җыенасың, ходавәндә?! — диде карт, тыныч булырга тырышып. — Мине яңа власть та үтерә алмады, сөрген дә бетермәде, син юк итәргә уйлыйсыңмы? Нигә син карт кешегә мылтык төбисең? Аллаһ каршында ни дип җавап бирерсең?!

— Ә менә хәзер тикшереп карыйбыз инде, кемнең Алласы көчлерәк, — диде кара-чутыр, телен чак әйләндереп. — Курыкма, без сине тау ияләренә корбан итеп бирәбез, мондый дәрәҗә бөтен кешегә эләкми...

Асылгәрәй карт бу исерекнең чынлап сөйләгәнен аңлап алды...

Ул аны атып үтерергә җыена иде...

— Тимә миңа, минем балаларым, гаиләм бар, үз өстеңә гөнаһ алма, — дип әйтеп карады Асылгәрәй карт, бурның каткан күңелен йомшартырга тырышып.

Әмма ул Асылгәрәй картның сүзләренә колак та салмады, чөнки ул белә — аларны күргән кеше исән калырга тиеш түгел иде. Чөнки шулар аша эзгә төшәргә мөмкиннәр. Бу картны монда беркем чакырып китермәде, беркем эзләп тә йөрмәячәк. Алар булмаса да, ул моннан барыбер исән-сау чыга алмас иде, чөнки моннан чыгу юлы юк. Бер якка да...

Сүзләре тәэсир итмәгәч, карт соңгы адымга барып карарга булды. Аның кесәсендә елгадан тапкан алтын бар, ул аларны, төреп, төрле кесәләренә яшергән иде. Ул исерек бурга шуны биреп котылмакчы булды. Теге икесе учак янында тәгәрәп йоклап яталар, монысы, бәлки, алтынга алданыр, үзенең явыз ниятен онытыр.

— Син миңа тимә, мин сиңа алтын бирәм, тапкан урынын да күрсәтәм, — диде ул, вакытны мөмкин кадәр сузарга тырышып.

«Алтын» сүзен ишеткәч, кара-чутырның күзләре ут булып яна башлады...

Алар менә күпме вакыт эзлиләр инде ул алтын елгасын, әмма һаман таба алганнары юк. Ә бу карт беләм, ди. Алтын бирәм, ди. Әмма моны башкалар ишетергә дә, белергә дә тиеш түгелләр. Алар әнә бернәрсә белмичә йоклый, шул вакытта бу карт белән алыш-биреш ясарга кирәк. Тегеләрнең башына җитәргә һәм карт белән алтын елгасын эзләп китәргә...

Кара-чутыр, мылтыгын җиргә куеп, карт янына йөгереп килде...

Аның кулында, чыннан да, алтын бөртекләре ялтырый иде...

Моны күреп, ул чинап җибәрде, картның кулыннан төенчеген тартып алды һәм, җиргә чүгеп, алтынны саный башлады. Ул аны бер кояшка тотып карады, бер тешләренә тидереп алды, учларында сикертте. Хәзер бөтен дөнья аның ку-

лында иде. Бу картны хәзер берничек тә үтерергә ярамый, чөнки ул аны хәзинә чыккан җиргә алып барачак иде...

Шул вакыт, нәрсәдер әйтергә теләгәндәй, буыла-буыла Сарбай өрә башлады. Аның тавышына башкалар да сикерешеп тордылар. Кара-чутыр тизрәк мылтыгына ябышты һәм алар ягына төбәп ата башлады. Корал тегеләрдә дә бар иде, алар да мылтыкка ябышты, әмма барысы да исерек булганлыктан, кая атканнарын да белмиләр иде. Икенче караганда инде алар, бер-берләренә ябырылып, учак янында ауный башладылар. Су буе яман сүгенгән, авыртудан акырган, кычкырган, янаган тавышлар белән тулды...

Шуны гына көткәндәй, Сарбай яр буйлап аска таба чабып китте...

Ул Асылгәрәй картны да үз артыннан ияртер өчен телгә килеп сөйләми генә иде. Карт моны үзе дә яхшы аңлады, бу юлбасарлардан качу өчен иң җайлы вакыт икәнлеген сизеп алды. Карт белән эт аллы-артлы Агыйдел яры буйлап йөгерделәр. Караклар аңга килгәндә, алар бу урыннан шактый еракалашканнар иде инде. Карт белән бергә алтын елгасы турында хәбәр дә китеп бара иде. Кара-чутыр моны беренче булып сизде һәм җан ачуы белән картның артыннан атып җибәрде. Яралы хәлдә булса да, ул аңа кирәк иде, чөнки алтын елгасының кайдалыгын бары тик шушы карт кына белә иде...

Асылгәрәй картның сул җилкәсен нидер өтеп алган кебек булды. Әмма ул аңа игътибар итмәде, аңа тизрәк бу куркыныч урыннан качарга, ераклашырга кирәк иде. Артта ату тавышлары тынмады, әмма алар инде хәзер шактый еракта ишетелә иде. Куа килүчеләр күренмәде, чөнки каракларның икесе инде үлеп ята, ә өченчесе, маңгаенда тамгалысы, яралы хәлдә аны куып җитәрлек түгел иде. Әмма ул атуын һаман дәвам итте, карт аңа нинди хәлдә булса да кирәк иде...

Асылгәрәй картның сул як җилкәсе үтереп сызлый башлады. Ул, йөгергән уңайга, аны учы белән кысып тотты. Иңбашы юеш иде, картның кулы канга манчылды. Димәк, теге мәлгунь аны яралаган, ядрә җилкәне кыеп үткән...

Йөгерә торгач, картның хәле бетә башлады, күз аллары кинәт кенә караңгыланып китте, аркасы юешләнеп чыкты. Аннан әллә кан, әллә тир ага иде. Әмма карт туктап калырга да курыкты, теге юлбасарлар артыннан куа киләләр кебек тоелды. Аның инде алга барырлык та рәте калмаган иде. Ул, хәле бетеп, Агыйдел ярындагы агачка сөялде, ярдәм көтеп елга өстенә карады. Җилкәсе бик нык сызлый, башы әйләнә, тәненнән каны китеп бара иде. Каны белән бергә җаны да күкрәк читлегендә бәргәләнә башлады.

Карт җиргә чүгеп төште. Агачка сөялде, кыйблага карап

тәһлил әйтте, Аллаһ сүзе белән күзләрен йомды. Иреннәренә шаһәдәт кәлимәсе килде, җаны якты дөнья белән хушлашты. Соңгы тапкыр күреп калыйм дип, ул күзләрен ачты һәм су буйлап бер каекның төшеп килгәнен күрде. Көймәдә улы Гыйлемгәрәй утыра иде. Карт тетрәп китте — каян килсен монда Гыйлемгәрәй? Ул әллә язмыш дәрьясы буйлап әтисен алырга киләме? Әллә соң ул саташамы, әллә соң инде китеп барамы? Нигә аның бөтен тәне әле ут булып яна, әле боз булып өши?

Карт тагы елга өстенә карады һәм тагы ялгыз каекны күрде...

Бу юлы көймәдә улы Солтанхәким утыра иде...

Тукта, Солтанхәким агач төбендә ятып калды бит, ничек монда хәтле килеп җитә алган ул? Әллә әтисен коткарырга, үзе белән алып китәргә килгәнме?

Юк, көймәдә Сәгыйть түгелме соң? Сәгыйть Урал аръягында, далада ятып калды бит инде, ничек ул бирегә килә алсын? Ялгыз каек томан арасында бер күренә, бер юкка чыга, суда ишкәк чупылдаган тавышлар гына ишетелеп китә.

Карт аңа кычкырмакчы, туктатмакчы була, әмма тавышы чыкмый...

Каек менә инде аның турына да килеп җитте, инде менә үтеп тә бара...

Котылырга бердәнбер өмет, мөмкинлек карт яныннан шуып, үтеп бара иде...

Шулчак Сарбай, күккә карап, сузып-сузып улый, үксеп елый башлады...

Аның шомлы тавышы, хәвеф билгесе булып, Агыйдел өстенә таралды, каршыдагы биек тауларга барып бәрелде. Һәм көймәдәге малайга да ишетелде. Ул сискәнеп яр буена карады һәм анда җиргә тезләнгән картны күрде. Янында эте үксеп-үксеп елый, кайгы барлыгын хәбәр итә иде.

Малай каегын тиз генә шул якка борды, яр буендагы карт янына килеп туктады. Ул күрде: карт яралы иде, аның җилкәсеннән кан саркып тора. Биредә тагы бераз ятса, ул каны агып бетеп үләргә мөмкин иде. Малай картны тизрәк көймә төбенә алып кертеп салды, үзе дә сикереп кереп утырды. Алар артыннан Сарбай да көймәгә сикерде, чөнки ул хуҗасын берничек тә ташлап калдыра алмый иде.

Карт хәлсез куллары белән җилкәсен кысып тотты, аккан канны туктатырга итте. Малай да рәт белә икән — тиз генә картның күлмәк җиңен ертып алып, яралы иңбашын кысып бәйләп куйды. Су белән картның битләрен чылатты, кулларын юдырды. Аннан тагы ишкәкләренә тотынды. Болардан соң карт та бераз тынычланып китте, авыртуы да бераз ычкындырып торган кебек булды. Тыныч кына су чу-

пылдаган тавышка карт эреп йокыга китте. Көймә аны бишектәге кебек тибрәтә иде. Агыйдел суы әллә кайларга агызып төшеп бара иде. Күзләрен йомганчы, карт шуны аңлап өлгерде: Аллаһы Тәгалә бу баланы аңа ярдәмгә җибәргән иде. Һәм ул аңа зыян салмаячак, юлында ярдәмче булачак иде...

Көймә, агым уңаена тибрәлеп, Агыйдел буйлап аска төшеп китте. Ул әле биек-биек кыялар яныннан ышкылып диярлек үтте, әле елга белән бергә киң үзәннәргә атылып килеп чыкты, әле кара урманнарга кереп юк булды. Әйтерсең лә Асылгәрәй карт балачак бишегендә гомер елгасы буйлап агып төшеп бара иде. Һәм бу көймәнең кайчан, кайда туктыйсын бер Аллаһ кына белә иде...

* * *

Маһинур абыстай кайтканда ук авыру иде, идән астына төшкәч, бөтенләй бетте...

Коры ютәл күкрәгенә ябыша да, тынны буып, йөткертә башлый. Бер йөткерә башласа, сәгатьләр буе йөткерә. Моны күреп, өйдәгеләр нишләргә белми, бигрәк тә Сабира өзгәләнә, әнисе өчен ике юлның кайсын сайларга белми — өскә чыкса, аны төрмә көтә, аста исә ул чирдән бетәргә мөмкин. Үзе өйдә вакытта ул әнисен идән астында тотмады, ишектә чит кеше күренсә, тизрәк аска төшерде.

Ә Шайтан Шакир бөтенләй әрсезләнде, козгын кебек көн саен алар тирәсендә бөтерелә. Бер кергәч, чыгып та китә белми, ичмасам, сәгатьләр буе теленә салынып утыра. Тимерче Гариф аны бер селтәнүдә капканың теге ягына тотып ата ала алуын, әмма власть алар кулында бит, бәйләнсәң, башың төрмәдән чыкмас. Сугыш батыры дип тә тормаслар, хәзер йорт аралаш куылган да сөрелгән...

Ә Сабира әнисе өчен ут йота...

Салкын түбән өйдә бөтенләй авырып китәр дип курка, йөткерә башлар да, Шайтан Шакир ишетеп алыр дип хәвефләнә. Шайтан Шакир барында әнисе аста берничә тапкыр шулай йөткерә башлагач, Сабира дөбер-шатыр идән өстендә йөрергә, кычкырып сөйләшергә тотынды. Ул күренгәч, Гариф та кычкырыбрак сөйләшә башлый, балалар да дөбер-шатыр киләләр, аларны беркем тыймый. Шулай итеп, алар да әбиләренә өйдә чит кеше барлыгын хәбәр итәләр, аның йөткерүен каплыйлар...

Шулай итеп, үз кызында кача-поса яшәп, инде җәй дә үтеп бара иде. Ә Асылгәрәй карт һәм балалар һаман күренми...

Бу дөньяда Маһинур абыстайның бөтен көткәне бары тик

алар гына. Инде җәяү кайтсалар да, әллә кайчан кайтып җитәрлек бит. Нәрсә булды аларга, ник берсе-бер күренми, хәбәр бирми? Ә монда кайткач аларны нәрсә көтә? Җиңнәрен сызганып Шайтан Шакир көтеп тора. Туган җирләрендә менә шулай базга качып яшәү көтә. Тотылсалар, төрмә, яңадан сөрген көтә... Боларны хәзер Маһинур абыстай да бик яхшы аңлый инде...

Сөргендә вакытта ул Аллаһтан бер генә нәрсә сорады — туган ягына кайтып җитүне, мәңгегә шул туфракта калуны. Гүр иясе булып ач далада, уртак чокырда ятасы килмәде аның. Аллаһ аны исән-сау кайтарып җиткерде. Инде Маһинур абыстай үзе дә сизенә — аның гомере ахырга якынлашып килә. Аның хәзер дөньяда бер генә теләге калды — ирен күреп, бәхиллеген алу. Ире исән булса, балаларга юкка чыгарга ирек куймас. Аның исәнлеген белсә, ул да тыныч күңел белән китәр иде. Ул хәзер Аллаһтан ире кайтып күзенә күренгәнче гомер сорый. Ә көннәре санаулы калып бара иде...

Җәй уртасы үтүгә, көннәр кинәт кенә салкынайтып җибәрде...

Тоташ яңгырлар башланды, кояшның җылысы сүрелде, авыл өстен болытлар каплап китте. Бәрәңге базында түгел, өйдә дә салкынча, дымлы иде, алар җәй көне мич ягарга мәҗбүр булдылар. Көннең болай кинәт үзгәрүе Маһинур абыстайга да начар тәэсир итте, бер ютәлли башласа, ул инде туктый алмас хәлгә килде. Моны күреп, Сабира кискен карарга килде. Ул әнисен түбән өйдән өскә чыгарырга булды, аның өчен әнисенең сәламәтлеге кадерле иде.

— Әни, мин сине бүтән идән астына төшермим, — диде ул, әнисен төнлә мунча керергә алып менгәч. — Бүгеннән өстә яши башлыйсың, ни булса да булыр инде.

— Шайтан Шакир көн дә диярлек керә бит, кызым, — диде ана, ни әйтергә дә белмичә.

— Керсә керер! — диде Сабира һәм үксеп елап җибәрде. — Менә синең урынга мине алып китәр! Үзем китәм төрмәсенә дә, сөргенenә дә. Әмма сине яңадан базга төшермим...

Ана белән кыз кочаклашып озак еладылар.

Һәм Маһинур абыстай яңадан идән астына төшмәде. Сабира аны, бөтен барлыгын биреп, бала караган кебек карый башлады, әмма ана сүнгәннән-сүнә барды. Ул мич арасындагы җылы урыныннан сирәк чыга башлады, көннәр буе тәхлил әйтеп, дога кылып, намаз укып ята иде. Оныклары аңа әле җиләген, әле җимешен җыеп китерәләр, иртә-кич җылы сөт эчерәләр, әбиләрен иң тәмле ризыклар белән сыйларга тырышалар. Ә ул һаман ачтан үлгән балаларын уйлый, тамагына ризык бармый. Исәннәре турында бер хәбәр ишетергә тилмерә.

Һәм хәбәр озак көттермәде...

Яңгырлы көннәрнең берсендә, бөтен урам пычрагын ияртеп, өйгә Шайтан Шакир килеп керде.

Ул, гадәттәгечә, кызмача иде, үзе ялт-йолт килеп карана, тыңлый. Шулчак мич арасында буыла-буыла Мәһинур абыстай ютәлли башлады. Моны ишетеп, өйдәгеләрнең коты чыкты, хәзер Шайтан Шакирдан берни дә яшереп булмый иде. Һәм ул туп-туры тавыш ишетелгән якка китте, чүпрәк чаршауны сыдырып ачты һәм урын өстендә яткан Мәһинур абыстайны күрде. Ниһаять, ул эзләгәнен тапты! Югыйсә җәй буе районнан аның башын ашадылар, шушы контрларны таптырдылар. Имеш, алар җәй башында ук гаиләләре белән Магниткадан качкан булганнар, инде күптән кайтып җитәргә тиешләр икән. Һәм авылда күренү белән, Шайтан Шакир аларны Бөгелмә төрмәсенә озатырга тиеш иде, чөнки качып кайту ул инде башка статья. Менә хәзер берсе капкынга килеп керде, димәк, башкалары да берәм-берәм эләгәчәк.

— Кайчаннан бирле качырып яткырасың бу кулак калдыгын?! — дип җикеренде ул, бер Сабирага, бер тынсыз калган абыстайга карап.

— Менә шушы көннәрдә генә кайтып керде әле, — диде Сабира, ни әйтергә белмичә.

— Ялганлыйсың, кулак калдыгы, социализм дошманы! — дип акырып җибәрде Шайтан Шакир, бөтен өйне дерелдәтеп. — Алар инде җәй башында ук качкан булганнар!

— Качсалар, кайда соң, алайса? — диде Сабира, аның кычкыруыннан курыкмыйча. — Качкан кеше бер кайтып җитә ул, Урал арты дөнья чите түгел. Кайда соң, алайса, алар?

— Беркая китә алмаслар, эләктерерләр, — диде Шайтан Шакир, кулларын уып. — Менә монысы капкынга төште бит. Ике кызларын кире тотып җибәргәннәр инде. Юлда кәкерәймәгән булса, картлач та кайтып җитәр, малайлары да. Һәм без аларны… шап!

Шайтан Шакир үз эшеннән канәгать иде…

Әйтерсең яу кырында иң зур дошманын тоткан…

Бу гаиләнең язмышы хәзер аның кулында иде…

Ә кем уйлаган? Моннан унбиш ел элек кенә ул Асылгәрәй картның ишегалдын себереп йөри иде бит. Ул вакытта карт түгел иде әле, дөнья җимереп яшәп яткан данлыклы мулла иде ул. Сабира да әле ул вакытта җиләк кебек яшь кыз иде, аның кәләшен урлап качкан Равил үсмер малай иде. Мәһинур абыстай да яшь иде әле ул вакытта, кәс-кәс басып кына тарантаска утырып, парлап кунакка чыгып китәләр иде. Балалары кайсы уйнап кала, кайсы укып йөри, кайсы табигатьтә хозурлана. Ә Шайтан Шакир эшли, аларның мал абзарларын чистарта. Дөрес, хәзрәт яхшы түли иде, ризыктан, өс-баштан өзмәде аларның гаиләсен. Ә Шайтан

Шакирлар авылда иң фәкыйрь гаилә иде. Әтисе эчеп гомер буе әнисен кыйнады, гарип калдырды, кабергә кертте. Балалар көтүләре белән ач булдылар, урамда кундылар. Менә шунда Асылгәрәй хәзрәт, кызганып, аны үзенә эшкә алды. Һәм Шайтан Шакир ул вакытта бөтенләй башка төрле дөнья, башкача яши торган кешеләрне күрде. Малай аларның бу тормышыннан, балаларының мондый бәхетеннән гомер буе үлеп көнләште, үзләрендәге мәхшәрдә аларның гаепләрен күрергә тырышты. Кем уйлаган унбиш елдан соң Морза Мирзаяннар нәселе шулай пыран-заран килеп бетәр дип? Менә бит совет властеның көче, менә бит партиянең кодрәте, кемнәрне кем итте?!

Аның уйларын сизгәндәй, мич артыннан Маһинур абыстайның зәгыйфь тавышы ишетелде:

— Нигә дип безгә шулхәтле каныктың син, Шакир энем? Син безнең күз алдында үстең бит, без сине рәнҗетмәдек, тамагың тук, өстең бөтен булды.

— Сезнең тизәкне җыепмы?! Сез мине, үсмер баланы, хезмәтче итеп тоттыгыз, кулак тәреләре! Һәм совет власте сезне белеп илдән сөрде!

— Бездә эшләмәсәң, җыелып ачка үлә идегез бит ул исерек атагыз белән. Хәзрәт сине жәлләп эшкә алды, бөтен гаиләгезне ашатып, киендереп торды, рәхмәтең шушымы аңа? Шуның өчен безне сөргенгә сөрдеңме? Аллаһ алдында җавап бирүдән курыкмыйсыңмы?

Шайтан Шакир, корт чаккандай, баскан урынында сикереп куйды...

Ул эчеп үлгән әтисен дә, әтисе кыйнап үтергән әнисен дә искә төшергәнне яратмый иде. Ә бу Коръән кортлары шуның белән биткә бәрергә генә торалар. Яңа властьны күрә алмыйлар. Совет мондыйларны бик белеп сөргенгә куды, мондыйлар белән яңа тормыш корып булмый, булмый!..

— Сезне мин түгел, совет власте сөргенгә сөрде, буржуй тәреләр! — дип кычкырды Шайтан Шакир, карчыкның борын төбендә йодрыкларын уйнатып. — Һәм бик дөрес эшләде сездәйләрне куып. Чөнки мондый чит элементлар белән социализм төзеп булмый, сезнең кебек кулак-контрлар колхозларга эшләп китәргә ирек бирмиләр...

Шайтан Шакир тыгылып, туктап калды, чөнки аның ятлап алган кызыл сүзләре беткән иде. Теге елларда хәзрәт күпме тырышса да, аны укырга-язарга өйрәтә алмады, яңалифкә дә аның башы җитмәде. Ул, тырнаштырып, кул куярга гына өйрәнде. Шуңа күрә ул авылның иң гыйлем, иң чибәр кызына өйләнергә теләгән иде, яңа тормыш төзегәндә ярдәмчесе булыр дип. Ә ул менә шушы кулакларның малаен — Равилне сайлап алды. Язылышкан җирдән аның бе-

лән атка утырып качты. Кайсы яктан гына килеп карасаң да, Морза Мирзаяннар нәселе Шайтан Шакирның юлына аркылы төшкән булып чыга, ягъни аның өлешенә кергән. Һәм монда аларның нәселе калмаска тиеш. Бу кортканы да тиз арада Бөгелмәгә озатырга кирәк, ятмасын монда кеше котыртып, дөнья сасытып. Ул аны бүген үк биредән сөрер иде, әмма урамда коеп яңгыр ява, атлар җигелмәгән, үзенең дә кәеф башка, Бөгелмәдә күренеп йөри торган түгел.

— Бәхетең, кортка, бүген яңгыр ява, югыйсә хәзер үк Бөгелмәгә олактырыр идем мин сине, — диде ул, яхшылык эшләгәндәй кыланып. — Иртәгә таң белән әзер тор. Кара аны, берәр мөгез чыгарасы булмагыз, югыйсә бөтен гаиләгез белән Себер китәчәксез.

Өйдәгеләр тынсыз калдылар...

Әле ниндидер өмет бар иде, Шайтан Шакир авыру карчыкка кагылмас дип уйлаганнар иде. Ә ул әнә иртәгә үк әзер булырга куша. Ничек инде авыру, үләргә торган карчыкны төрмәгә озатасың? Шулхәтле җирләрдән туган җиренә кайтып егылган кешене яңадан сөргенгә сөрәсең? Ул анда барып та җитә алмаячак бит, юлда ук үләчәк...

— Әнинең хәле авыр, Шакирҗан, — диде Сабира, нишләргә белмичә. — Барып җитә алмаячак ул анда... Кагылма әнигә, әйтмә аны монда күрүең турында, синнән бу хакта беркем сорамый бит...

— Миннән көн саен алар турында сорап торалар! — диде Шайтан Шакир кәперәеп. — Мин монда һәркем өчен җавап бирәм, мин монда совет власте! Син мине шул властька каршы эшләргә котыртасыңмы, мулла калдыгы?! Үзеңнең дә Себер китәсең киләме?!

— Дәшмә, кызым, — диде Маһинур абыстай, боларны ишетеп. — Шайтаннан мәрхәмәт сорама... Алладан сорыйк, ни язган, шул булыр...

Һәм карчык, тыны бетеп, буыла-буыла йөткерә башлады...

Сабира аның кайнар башын күкрәгенә кысты. Маһинур абыстайның ирен кырыйларыннан бәреп чыккан алсу кан аның алъяпкычына тамды. Моны күреп, кечкенә балалар кычкырып елап җибәрде, Гарифҗан су алып килергә йөгерде. Шайтан Шакир, күн итекләре белән дөп-дөп басып, өйдән чыгып китте. Аның артыннан идәндә пычрак эзләре генә торып калды...

Маһинур абыстайның бит-кулларын салкын су белән юып, җылы чәй эчертеп, урынына яткырдылар. Ул шактый вакыт тып-тын, бернәрсә сөйләшмичә ятты. Аяк очында кызы Сабираның мышкылдап елаганы гына ишетелә иде.

— Кайгырма, кызым, Алла язмаган эш булмас, — диде ана,

кызын юатырга итеп. — Барысы да Алла кулында. Һәм ул мине яңадан Шайтан Шакирлар кулына бирмәс, иншаллаһ...

Сабира, берни аңламыйча, әнисенә карап торды...

Нәрсә әйтергә тели ул? Шайтан Шакир иртәгә таң белән килеп җитәчәк бит, аны Бөгелмә төрмәсенә алып китәчәк. Авылдан чыгып качар урын да юк, качсаң да тотачаклар. Ничек итеп ул әнисен яңадан төрмәгә биреп җибәрсен?! Җибәрмәс өчен нәрсә эшләсен? Сабира, бәргәләнеп, җавап эзли иде...

— Кызлар исән икән, Аллага шөкер, — диде ана, җиңел сулап. — Аларны шул станциядә үк тотып алган булганнар икән, мин шуңа күрә таба алмаганмын... Ә мин Уфада күпме көттем аларны, монда кайткач күпме көттем... Менә бит тәкъдирдә ничек язылган булган...

Сабира Шайтан Шакирның бу сүзләрен онытып ук җибәргән иде, ә әнисе өчен бу бик мөһим хәбәр иде...

— Болай булгач, әти белән Солтанхәким дә исән булырга тиешләр, әни, — диде ул, аны юатырга теләп. — Тотып, анда кире кайтармаганнар икән, димәк, алар юлда. Монда кайтып киләләр...

— Мин дә шулай уйлыйм, — диде карчык сабыр гына. — Һәм көтәм, кызым... Мин атаңны күрмичә китә алмыйм... Бер җиргә дә...

Карчык башка сүз әйтмәде, әкрен генә күзләрен йомды...

Ул тәкъдиргә ышана һәм барысын да Аллага тапшырган иде...

Ул бирегә инде бер җиргә дә китмәс өчен, бөтенләйгә кайтканын белә...

Һәм әкрен генә соңгы сәгатьләре якынлашканны да сизә... Шайтан Шакирлар барыбер өлгермәячәк. Ә Асылгәрәй хәзрәт өлгерергә тиеш. Карчыкның күңеле шулай сизенә. Чөнки алар бәхилләшмичә аерыла алмыйлар...

Карчык яткан җиреннән генә намазларын укыды, күңеленнән теләк-догаларын әйтте. Аның соңгы теләге ирен күрү һәм Зәйтуганда җирләнү иде...

Ул бирегә шуның өчен кайтты...

Инде китмәскә дип кайтты...

Һәм ул моны яхшы белә иде...

Бу төндә аның күз алдыннан бөтен гомере үтеп китте...

Һәм аның бөтен гомере Зәйтуган белән бәйләнгән иде. Бала чагы һәм яшьлеге үткән Колшәриф инде хәтер томанына күмелгән, ә Зәйтуганны бернәрсә күмә алмады, хәтта сөрген газаплары да. Аны хәтта Магнитканың кара көннәре дә басып китә алмады, ул, әле яшел атау булып, әле ап-ак карга чумып, гел аның каршына килә иде. Чөнки Зәйтуганда Мәһинур абыстайның иң бәхетле көннәре үтте. Биредә

аның тугыз баласы туды, янында һәрвакыт әүлияларга тиң ире булды. Нинди авыр, борчулы елларда да ул гаилә йөген түкми-чәчми алып барды. Авыл аша аклар да, кызыллар да үтте, ачлыгы да, сәнәкчеләр фетнәсе дә булды, ә гаилә, йорт-җир үз урынында калды. Чөнки Асылгәрәй хәзрәтнең гыйлеме, дәрәҗәсе алдында барысы да чигенә, кечерәеп кала иде. Ул, кыя кебек, йорт-җирне, гаиләне, хәтта Зәйтуганны җил-давыллардан саклап торды. Изге догалары белән, зирәк акылы белән...

Ә менә бу афәттән саклана алмадылар алар...

Колхозлашу дигән сылтау белән, кулак, дип, иң башта алар гаиләсенә ябырылдылар. Аннан башкаларны кыра башладылар. Кемне аттылар, кемне астылар, кемне илдән сөрделәр. Зәйтуганның әле мондый хәлне күргәне юк иде. Дөньяның асыл ире Асылгәрәйне, аның гаиләсен дә шушы газаплар һәм мәсхәрәләр аша үтәргә мәҗбүр иттеләр. Аның гөлләр арасында үскән чәчәк кебек балаларын да...

Менә алар, җитәкләшеп, берәм-берәм Маһинур абыстай каршыннан үтәләр, гүя аның белән күрешеп, бәхилләшеп калырга телиләр. Аларның Зәйтуганда иң бәхетле көннәре икән. Әнә игезәкләре Рәйсә белән Мәрзия гөлләргә су сибеп йөриләр, аларның иң яраткан эшләре шул иде. Алар һәр чәчәкнең исемен беләләр, кышларын аларны аллы-гөлле итеп рәсем дәфтәрләренә ясыйлар, сөлгеләргә чигәләр. Әнә кулына һәрвакыт китап тоткан Солтанхәким, ул кечкенәдән гыйлемгә хирыс булды, ун яшендә шаулатып Коръән укый иде, намазын калдырмады. Саҗидәсе, кул эшләреннән тыш, өй эшләрендә дә бик булган, тырыш бала иде, бер дә әнисе кушканны көтеп тормады, барысын ялт итеп җыештырып куя иде. Сәгыйте дә гел әтисенә хуҗалык эшләрендә булышырга тырышты, яшьтән кул арасына керә башлады. Гыйлемгәрәйдә ике якка да бар иде — дингә дә, дөнья тормышына да омтыла иде балакай. Атасы кебек, икесен бергә алып барырга тырышты. Намазын да калдырмады, дөнья рәтен дә белә иде. Гайшәсе кечкенәдән гаять әдәпле, тырыш бала булып үсте, ул йортта әнисенә алмаш иде. Бөтен эне-сеңелләрен ул карап үстерде, аларны эш рәтенә өйрәтте. Олылары, Равил белән Сабирасы, кыюлыклары белән аерылып тордылар, шуңа күрә тормышларын да үзләре теләгәнчә кордылар. Сабира үсеп җиткәндә, инде дөньялар үзгәргән иде, мулла кияүләр заманы үткән иде. Ул авылда тимерче егеткә кияүгә чыкты, яратып өйләнештеләр, яратып яшәп яталар, мең шөкер. Димәк, башта ук тәкъдирдә шулай каралган булган, Сабираның биредә төпләнеп калуы язмыш дәфтәренә язылып куелган булган. Равиле дә тормышын үзе теләгәнчә башлап җибәрде — авылның иң чибәр кызына гашыйк булды һәм аны Шай-

тан Шакир тырнагыннан урлап алып китте. Бәлки, Шайтан Шакир хәзер шуның үчен дә аладыр, Морза Мирзаяннар нәселен шуның өчен газаплыйдыр...

Әмма Маһинур абыстайның бу минутларда газап турында уйлыйсы килмәде. Ул балаларыннан разый иде. Инде хәзер барысы да Аллаһ кулында. Балалары да югалмас, иншаллаһ! Калебләрендә иманнары бар, берсенә таянычка икенчесе бар... Һәрхәлдә, алар бу газаплардан котылырга омтылып карадылар, кимсетелүләргә ризалашып ятмадылар, мөмкинлек булу белән качып карадылар... Маһинур абыстай бу адымга баруларына һич кенә дә үкенми, качарга ниятләп, алар дөрес иттеләр. Бер көн, бер мизгел ирек барысын да алыштыра иде. Алар бер көн булса да иректә яшәп калдылар, чәнечкеле тимерчыбыклардан, бараклардан, мылтыклы сакчылардан котылып тордылар. Бер көн булсалар да үз ихтыярларында булдылар, ирекнең тәмен белделәр. Хәзер алар аны мәңге онытмаячак инде...

Әлхәмдүлиллаһ, ул үзе авылга хәтле кайтып җитә алды...

Ул, күкрәк тутырып, туган як һавасын сулый, Зәйтуганның чишмә суларын эчә, кызы кулыннан хәләл ризык ашый... Һәм аның соңгы йорты да Зәйтуган туфрагында булачак, иншаллаһ...

Таң алдыннан карчык әллә йоклап китте, әллә аңын югалтып алды — ул бөтенләй үзе күрмәгән-белмәгән дөньяга китеп барды. Бу җирләр аңа таныш та кебек, юк та. Бу кешеләр аңа бик якын да, бераз чит тә кебек. Әнә башлары болытларга тигән биек таулар артында зур шәһәр җәелеп ята. Анда кыя-таулар кебек биек-биек йортлар, ярты шәһәрне каплап киткән завод торбалары. Шуларның барысын да узып күккә атылган мәчет манарасы. Карчыкның әле беркайчан да мондый матур һәм мәһабәт мәчет күргәне юк иде. Зур елганың ярында, шәһәр уртасында, ул әйтерсең лә җир астыннан үсеп чыккан. Ә манарасы, Урал тауларын да үтеп китеп, җиде кат күккә менеп җиткән. Шул манарадан җиде кат күкләргә тезелешеп аның балалары менеп килә. Иң алдан Асылгәрәй карт белән Маһинур абыстай атлыйлар, алар артыннан ишле, зур нәсел килә. Равил һәм аның балалары, Сабира һәм анықылар, Гайшәнең гаиләсе, Гыйлемгәрәй ялгызы, Сәгыйть ялгызы, Сажидә ялгызы, Солтанхәкимнең балалары, Мәрзиянең гаиләсе, Рәйсә ялгызы. Һәм оныклар, аларның балалары, балаларның балалары. Әнә җиде кат күктәге манарадан Солтанхәким бөтен шәһәргә яңгыратып азан әйтә. Азан тавышы Урал тауларына кадәр барып җитә, кырык сыртны исән-имин узып, туган якларга кайтып керә. Биредә, Зәйтуганда да, элеккеге мәчет урынында зур таш мәчет басып тора, аннан Сабираның кече улы азан әйтә. Тик ул да Солтан-

хәким кебек инде олы яшьтә, чәчләре ап-ак. Монда, Асылгәрәй картның туган нигезендә, бөтен нәсел җыелган...

Шул ук вакытта бу хәлләр узган заманнарда да бара кебек...

Гөлләр арасында, үз йортында Мәһинур абыстай йөри...

Аның яшь чагы икән, ул Асылгәрәй хәзрәтнең мәчеттән кайтуын көтә...

Чәчәкләр арасында, җәйге бакчада табын корылган, чәй әзерләнгән. Өстәлдә — җәннәт ризыклары, бакчада — баш очында — оҗмах кошлары сайрап тора. Мәһинур абыстайның күңелендә шундый рәхәт тынычлык, әйтерсең лә ул үз гомерендә бер кайгы-хәсрәт күрмәгән һәм күрәчәк тә түгел. Аның күңелендә бер борчу юк, ул бәхетсезлекнең, чир-газапларның нәрсә икәнен белми. Бары тик рәхәт тынычлык, мәңгелек тынычлык. Әмма шул илаһи тынычлыкны бозып кемдер капка дөбердәтә. Тик аңа беркем җавап бирми...

Тупас тавыш тагы-тагы кабатлана.

Мәһинур абыстай авырлык белән генә күзләрен ача, әле генә җанын иркәләгән күренешләр, кешеләр, хатирәләр юкка чыга...

Таң яктысында ул үзен Сабираларның иске өендә күрә...

— Капкада кемдер бар, ахры...

Монысы кызы Сабира тавышы.

— Иртүк тагы Шайтан Шакир килеп җиттеме икәнни?

Монысы кияве Гарифҗан тавышы.

Мәһинур карчык шунда гына, тәмам айнып, аңына килә...

Әйе, бүген аны Бөгелмә төрмәсенә озатырга тиешләр...

Әмма ул үзенең инде моннан беркайчан да китмәячәген белә...

Тик башкалар моны белмиләр әле...

Һәм капка артында тавыш көчәйгәннән-көчәя бара...

Әмма беркем дә капка ачарга ашыкмый...

* * *

Көймә шуып кына Агыйделнең аръягына килеп туктады.

Асылгәрәй карт кай тарафка барганын, күпме барганын абайламыйчарак калды. Ул бу су юлын йокылы-уяулы хәлдә үтте. Яралы җилкәсе бер әрнеп сызлады, бер җибәреп, ычкындырып торды. Иң мөһиме — арттан куа килүче юк иде. Бу үсмер бала да мәрхәмәтле булырга охшаган, күңелендә миһербан булмаса, яр буена туктап, картны алып маташмас иде. Шуңа күрә Асылгәрәй карт аның кая, кемнәр янына алып баруына борчылмый, аларның яхшы кешеләр буласына күңеле белән ышана. Аңа хәзер кешеләрнең ярдәме бик кирәк, чөнки ул үзе яралы, үзе ач...

Карт малай артыннан чайкалып кына көймәдән төште, Сарбай да алар артыннан иярде. Алар шулай өчәүләп урман эчләтеп шактый бардылар, бераздан аланлык кебек бер ачык җиргә килеп чыктылар. Аланлыкның аргы башында берничә урамнан торган кечкенә авыл күренеп тора, рәт-рәт булып агач йортлар тезелеп киткән. Мондагы тәртиптән, чисталыктан ук биредә татарлар яшәгәнен чамаларга була. Урамнар киң, йортлар нык, капка-тәрәзәләр ялт итеп төрле төскә буялган. Ап-ак морҗалардан сыек кына төтен күтәрелә, бу таныш истән башлар әйләнә, Зәйтуган искә төшә. Асылгәрәй карт тыныч авыл тормышын бик тансыклавын, сагынуын аңлады, аның кешечә ятып ял итәсе, мунча керәсе килеп китте. Әмма иң башта яралы иңбашы белән нәрсәдер эшләргә кирәк иде.

Малай аны туп-туры үзләренең өйләренә алып кайтты. Әнисе урта яшьләрдәге татар хатыны булып чыкты, капкада Асылгәрәй карт күренүгә, ул ашыгып яулыгын бөркәнде, сызганган җиңнәрен төшереп куйды. Сарбай ишегалдында утырып калды, Асылгәрәй картны түр сәкегә кертеп салдылар. Малай әнисенә тиз-тиз генә нәрсәдер аңлатты, мөгаен, үзе күргән-белгәннәрне сөйләгәндер...

— Бар, улым, тиз генә Кафия әбиеңне чакыр, монда ансыз булмас, — диде әнисе, картның кан саркып торган ярасын ачып карагач.

Малай йөгереп чыгып китте.

Хуҗа хатын ул арада картка чәй ясап эчерде, алдына ит шулпасы, камыр ризыклары китереп куйды. Бу хәтле нигъмәтне күргәч, картның башлары әйләнеп китте, сызлануын да онытып, бисмилла әйтеп, ризыкка үрелде. Ул бигрәк тә икмәккә тилмергән иде, кайнар чәйнең тәмен оныткан иде. Ит шулпасын инде әйткән дә юк. Карт капкалаган арада, хуҗа хатын чаршау артына кереп китте, ашаганда аны уңайсыз хәлгә куясы килмәде, мөгаен. Кече якта аның нәрсәләрдер югалы, әзерләгәне генә ишетелеп торды.

Ул арада, Кафия карчыкны ияртеп, малай да кайтып керде.

Ул кимендә туксаннарга җитеп килә торган сырхаучы әби булып чыкты. Ягъни авылда кем авырса да, аны чакыралар, ул кендек әбисе дә, чыккан кулларны утыртучы да, сынган билләрне төзәтүче дә, яраларны ямаучы да икән. Карчык керә-керешкә Асылгәрәй картның иңбашын ачып карады һәм хуҗабикәгә су кайнатырга кушты, җиз ләгән, комган, чиста сөлге, чүпрәк-чапрак әзерләргә боерды. Калган кирәкле әйберләре аның үзе белән иде.

Шулар әзерләнгән арада, бераз сөйләшеп тә алдылар...

Агыйдел буендагы таулар арасындагы бу авыл Акбулат дип атала икән. Ул Бәзәл таулары ышыгына кереп утырган,

аны бер яктан тирән елга, икенче яктан биек сыртлар саклап тора. Исеменнән үк күренгәнчә, авыл, чыннан да, саф татар авылы булып чыкты, биредә шулай ук Мишәр очы, Типтәр очы дип аталган урамнар да бар икән. Кафия карчыкны Мишәр очыннан алып килделәр, ул шушы авылның абыстае да, кендек әбисе дә, табибы да булып чыкты...

— Җеназаны да үземә укырга туры килә, — диде ул, Асылгәрәй картны өнсез итеп. — Менә миңа кем укыр инде, башка рәтен белүче юк...

— Җеназа уку ир-атларга гына тиеш бит, — диде Асылгәрәй карт, сызлануын да онытып.

— Ә безнең авылда ир-ат юк бит, — диде хуҗабикә дә, сүзгә кушылып. — Менә минем малай биредә бердәнбер ир-ат, әмма ул яшь әле, рәтен белеп бетерми, ә өйрәтүче юк...

Карт телсез-өнсез торган арада, шабырдап су кайнап чыкты. Ләгән-тастымаллар, кирәк-ярак инде күптән әзер иде...

Мишәр карчыгы, үзе белән алып килгән әллә нинди үләнтамырларны салып, Асылгәрәй картка куе итеп чәй әзерләде, өшкереп аңа бирде. Бу хуш исле сәер чәйдән картның тәннәре йомшарып китте, зиһене таралгандай булды, бөтен күзәнәкләренә талгын рәхәтлек таралды. Аны чиста урын өстенә сузып салдылар, ярасын чистартырга әзерләнделәр. Үзенең мөселманнар кулында икәнлеген белгәнгә, Асылгәрәй карт тыныч иде, ул, Аллага тапшырып, күзләрен йомды. Һәм бераздан көчле дару үләннәренең тәэсирендә тирән йокыга китте...

Карчык аның берни сизмичә, үлем йокысы белән йоклавын көтте, Асылгәрәй картның борын төбендә үзенең үләнтамырларын төнәтте, һава алыштырды. Аннан соң җиңнәрен сызганып, бисмилласын әйтеп эшкә тотынды... Ул яшьләрчә җитез һәм төгәл хәрәкәтләр белән картның иңбашын утта кыздырган пәкесе белән ярып җибәрде һәм аннан کургаш кисәге тартып чыгарды. Пуля артыннан атылып чыккан кара канга ул бераз агарга ирек бирде, шулай итеп, тәнне алга таба агуланудан сакларга тырышты. Аннан кисәк кенә үзе белгән тамырларга басып, канны туктатты. Яраның тирә-ягын бераз чистартып алгач, ул үзе белән алып килгән сыекчаларны чыгарды. Бөтен өйгә балавыз һәм чәер исе таралды. Карчык аларны ярага сөртте, тагы бер тапкыр җәрәхәт өстендә төнәтмәсен төтәтте, аннан чиста чүпрәк белән тиз генә картның иңбашын бәйләп куйды. Ул зур осталык белән бу эшләрне башкарганда, Асылгәрәй карт бала йокысы белән йоклый иде. Карчыкның бертуктамый Коръән укуын ул йокы аралаш кына ишеткән кебек булды. Хуҗабикә исә, эш беткәнче, мишәр карчыгы биргән тамырларны яндырып торды. Бөтен өй эче баш әйләндергеч исләр белән тулды...

Менә карчык, эшләрен бетереп, чәй эчәргә утырды. Ә Асылгәрәй карт әле һаман йоклый иде...

Сарбай исә, ишек төбенә үк утырып, аның торуын көтә. Ул хуҗасының уянасына, үз янына чыгасына ышана, шуңа күрә өреп аны борчымый, хуҗа малай белән таныша тора. Бу малай да аңа ошый, чөнки ул Сарбайга кычкырмый, кайтуга, аның ашарына, эчәренә бирде. Бу йортта аның хуҗасына да, үзенә дә яхшы буласын ул эт күңеле белән дә сизә иде.

Асылгәрәй карт айнып күзләрен ачканда, өйгә тавык шулпасы исе таралган, шифалы үләннәрдән яңа чәй кайнаган, табын әзер иде инде. Карт башта үзенең кайда булуын аңышмыйча ятты, аннан барысы да исенә төште — яралануы да, көймә белән төшүе дә, бу йортка килеп керүе дә. Карчык аңа ниндидер үләннәр эчерде, һәм ул изрәп йокыга киткән. Алдан сөйләшенгәнчә, карчык аның ярасын юарга тиеш иде. Иңбашындагы көчле авырту бераз бетә төшкән, әмма сызлавы калган иде әле.

— Бу кургаш кисәге тәнеңдә шактый яткан, шуңа күрә каныңны да бераз бозган, — диде Кафия карчык, пуляны аңа күрсәтеп. — Шуңа күрә берничә көн каныңны чистартырга туры киләчәк. Юлың ашыгыч түгелдер бит?

Асылгәрәй карт бу беренче тапкыр күргән кешеләргә нәрсә дип әйтергә дә белмәде. Дөресен әйтергә ул курыкты, кайдан качуын яшерде.

— Терелсәм, кузгалырга иде инде, — дип кенә җавап бирде.

Картның аркасына зур ястык терәп, җайлап кына утыртып куйдылар.

Хуҗабикәнең исеме Сафия икән, ул юлаучы карт янында бөтерелеп кенә йөрде. Кыреындагы урындыкка яңа пешкән тавык шулпасын китереп куйды, чәен ясап китерде. Карт иң башта чәйгә үрелде, аның иреннәре бик кипкән, өзелеп эчәсе килә иде. Иплә кенә эчеп куйгач, ул хуҗабикәгә дә, Кафия карчыкка да зур рәхмәтләрен әйтте. Авырткан урын бераз сулкылдап торса да, карт үзен яхшы хис итә иде, әйтерсең лә иңбашларыннан утлы кисәү алып ташлаганнар. Күренеп тора, карчыкның кулы алтын, ул үз эшен яхшы белә иде. Кара урман уртасында иминлекне ул тотып тора иде.

Бергәләп ашап-эчә торгач, карт алар турында шактый белеп өлгерде.

Алар да бу юлаучы картның гыйлем иясе, дин кешесе булуын сизеп өлгергәннәр иде инде. Акбулат авылында күптән инде дин кешесенең дә, ир-атның да булганы юк иде, шуңа күрә алар Асылгәрәй картны бик сөенеп кабул иттеләр.

— Кая китеп бетте соң сезнең ир-атларыгыз? — диде Асылгәрәй карт бик гаҗәпләнеп.

— Бер өлеше соңгы совет сугышында бетте; аклар да, кызыллар да, урыслар да, башкортлар да кереп безнең ир-атларны аттылар, — диде Кафия карчык. — Калганнарын урмандагы кыргый бөрҗәннәр харап итеп бетерде... Сине дә шулар яраладымы?

— Әйе, шул кавем... Тау араларында мондый кыргый кешеләр яшидер дип белми идем мин. Үз күзләрем белән күргәч кенә ышандым... Алар өчен бернинди изге нәрсә юк икән, Аллам сакласын...

— Елгадан өскә менәрлек түгел, теге якка чыгарлык түгел, бөтенесен кырып бетереп баралар, — дип сүзгә кушылды хуҗа хатын да. — Без башта аңламадык ни булганын, ирләр аугa киткән җирдән дә юкка чыга, балыктан да. Безнең печәнлекләребез дә Агыйделнең аръягында бит, өске өлешендә... Ә анда алар кайдандыр килеп чыккан, җир асларын тишеп кереп яшәп яталар икән... Аларның бар кәсепләре кеше талау булып чыкты...

— Кеше үтерү, диген, — дип дәвам итте Кафия карчык. — Ул мәҗүси кавем үз илаһәләренә адәм баласын корбан итәләр икән... Тау араларына качып, борынгы кыргый диннәрен тотып яталар, алар өчен Алла да юк, мулла да...

— Соң монда берәр власть бардыр бит инде, нигә тыймыйлар бу явызлыкны? — диде Асылгәрәй карт гаҗәпләнеп.

— Маңгайларындагы тамганы күргәнсеңдер бит? — дип сорады Кафия карчык, аңа җавап итеп. — Патша заманында, эләксәләр, аларга шулай җәза бирәләр иде. Ә хәзер аларның барлыгын белүче дә юк, ике заман арасында кысылып калган кыргыйлар алар. Нәрсә телиләр, шуны эшлиләр; ничек телиләр, шулай яшиләр. Безнең тирәләргә килеп урнашулары бер бәла булды менә...

Асылгәрәй карт шул чакта үзенең бу явызлардан җиңел котылуын аңлады. Ул шунда бетәргә дә мөмкин иде бит. Аллаһы Тәгалә аны бу юлы да саклап калды, алардан качарга шушы баланы сәбәпче итте.

Ул арада өйгә малай үзе дә килеп керде. Аны да олылар янына ашарга утырттылар. Асылгәрәй карт аңа сынабрак карады — малай унике-унөч яшьләрендә, ябык кына җиңел гәүдәле, аз сүзле тыйнак бер үсмер иде. Аның ашавында да, үз-үзен тотышында да, сөйләшүендә дә әдәп-әхлак сизелеп тора, күрәсең, бала кечкенәдән дөрес тәрбия алган.

— Бу баланы миңа Аллаһы Тәгалә үзе сәбәпче иткәндер инде, — диде Асылгәрәй карт, аңа карап. — Юкса хәлләрем начар иде минем анда, бик начар иде... Алар сиңа да зыян салырга мөмкиннәр иде бит, улым, ул тирәдә нишләп йөри идең соң?

— Мин анда хәтле менмәдем, бу ярда идем, — дип җавап бирде малай. — Үзебезнең аланлыкта печән әзерли идем. Теге яктан аткан тавышлар ишетелүгә, ярга чыгып карадым... Сезнең йөгергәнне күрдем, эшнең нәрсәдә икәнлеген аңладым. Аннан яшереп куйган көймәмә утырып, сезгә ярдәмгә ашыктым. Ә тегеләр бер-берләренә атышып, сугышып калдылар, нәрсәдер бүлешәләр иде, ахрысы...

— Рәхмәт, улым, син мине зур бәладән коткардың, — диде Асылгәрәй карт. — Балаларым бәхетенәдер инде. Минем дә синең кебек улларым, кызларым бар бит... Инде исән генә була күрсеннәр...

Һәм Асылгәрәй карт түзмәде, бу яхшы кешеләргә үзенең тарихын сөйләп бирде. Үзенең Урал аръягындагы зур татар авылында мулла булып торуын, яңа власть килгәч, бөтен мөлкәтен, йорт-җирләрен тартып алуларын, ишле гаиләсе белән Магниткага сөргенгә сөрелүен әйтте. Үзләренең сөргендә нинди газаплар күрүләрен, ачлыктан һәм авырлыктан берничә баласының үлүен, аннан Магниткадан качуларын ул ачыргаланып сөйләде. Өйдәгеләр аны тетрәнеп, елап тыңладылар, адәм баласын бер гаепсезгә нигә болай җәзалауларын алар аңлый алмадылар. Аларга кушылып карт үзе дә елады. Аның бу хәлләр турында кемгә булса да сөйләп йөрәген бушатасы килде, бу миһербанлы кешеләр аны аңларга тиешләр иде.

— Менә шулай итеп, җәяүләп илгә кайтып барышым минем, — дип тәмамлады карт үзенең сүзен. — Бер улымны тау арасында бер яхшы кешегә калдырдым, чөнки баланың артык барырлык хәле юк иде, авырып калды. Хатыным, калган балаларым турында берни дә белмим. Инде Аллаһы Тәгалә аларны мондый явызларга очраудан сакласын, исән генә була күрсеннәр...

Өйдәгеләр, булдыра алганча, картны юаттылар, олы юлда мондый хәлнең юклыгын әйттеләр. Мондый кыргый кабиләләр бик тирән урман эчләрендә, Агыйделнең теге ягында гына калган икән инде. Бу якта алар юк икән, монда, очраса да, татар авыллары гына очрый икән. Ә татарлар, картка кайда очрасалар да, ярдәм итә килделәр, шуңа күрә юлны курыкмыйча дәвам итәргә булыр, иншаллаһ...

— Бу таулар әле күп калдымы икән кайтыр юлда? — дип сорады Асылгәрәй карт, тәрәзәдән каралып күренеп торган кыяларга күрсәтеп.

— Турыга китсәң, алар шактый әле, — диде Кафия карчык. — Юлны Агыйдел буйлап көймәдә төшеп кыскартырга була, безнекеләр шулай йөри иде. Әмма анда да син бу таулардан беркая котыла алмыйсың, аларның бу тирәдә иң күп һәм иң текә урыннары. Әмма сиңа бераз тернәкләнергә

кирәк әле, хәзрәт, мондый сәламәтлек белән юлга чыгарга ярамас... Каныңны чистартырга кирәк... Риза булсаң, мин сине үзем дәвалармын, иншаллаһ...

Карт өчен һәр көн кадерле иде...

Инде җәйнең уртасы үтеп бара, аңа, көннәр көзгә авышканчы, тизрәк Зәйтуганга кайтып җитәргә кирәк. Яңгырлар башланса, юл авыраер, тишек чабата белән ерак китеп булмас. Өс-башы да җиңел, көзге көн өчен түгел. Әмма бу хәлдә, ярасы бераз төзәлмичә, ерак юлга чыгу да куркыныч. Инде тәкъдирендә шулай язылган икән, бу мәрхәмәтле кешеләр янында бераз тукталыр, форсаттан файдаланып, аларга дин-исламны бераз аңлатыр...

Һәм Асылгәрәй карт тәвәккәлләп Акбулат авылында калды...

Карчык дөрес чамалаган икән — кургашын агуы канга шактый начар тәэсир иткән булып чыкты. Картның тәне яна башлады, ярасы янында үлек барлыкка килде. Ашыгыч чаралар күрмәсәң, ахыры начар бетүе дә бар иде. Шуңа күрә бу көннәрдә Кафия карчык аның яныннан китеп тормады — сөлек салды, ярып, начар канны агызды, җәрәхәткә тагы әллә ниләр сөртте, картка әллә ниләр кайнатып эчерде. Бу көннәрдә бер Кафия карчык кына түгел, бөтен авыл юлаучы картның гомере өчен көрәште, һәркем аңа үзенчә ярдәм итәргә ашыкты. Һәркем бу йортка үзенең иң яхшы ризыгын күтәреп килде, иң изге теләкләрен теләде, картның изге догасын алды. Асылгәрәй картның алдында балыгы да, тавыгы да, җиләк-җимеше дә өелеп торды. Әйтерсең лә Аллаһ аңа ач торган көннәре өчен әҗерен бирә, аңа озын сәфәр алдыннан туктап ял итәргә мөмкинлек тудыра иде...

Карт әкренләп тернәкләнә, савыга башлады. Инде таягына таянып, йорт каршына чыгып утыра, авыл урамнары буйлап йөреп килә. Сарбай бер адымга да аннан калмады, ул инде карт хуҗасын сагынып өлгергән иде. Дөрес, аның яшь хуҗасы да бик әйбәт кеше, ул хәзер Сарбайның иң якын дусты. Алар инде аның белән бу тирәдәге бөтен тауларны, урманнарны гизеп чыктылар, көн саен су буена төшәләр, балык тоталар, җәнлек аулыйлар. Әмма аңа карап Сарбай карт хуҗасын ташларга уйламый һәм ул кая барса да, аның артыннан йөгерә...

Асылгәрәй карт исә хәйран калып авылны күзәтә...

Хатын-кызлар гына яшәсә дә, шулкадәр тәртип, пөхтәлек монда, кешеләре шулхәтле миһербанлы, гади... Үз тырышлыклары белән малын да тоталар, утын-печәнен дә әзерлиләр, балта тотып, йорт-җирләрен дә төзәтәләр. Олы як барысы да намазда, әмма яшьләр инде тормышка батып баралар. Дөрес, авылда беркем дә уразасын калдырмый икән, әмма

яшь як инде намазны онытыбрак бара. Яшьләрнең күбесендә дини гыйлем юк, гап-гади нәрсәләрнең дә рәтен белеп бетермиләр. Һәм Асылгәрәй карт, биредә торган бер генә сәгатен дә әрәмгә уздырмыйча, аларга дин-ислам турында сөйләде, исламча яшәү үрнәген күрсәтте. Халык дөрес гыйлемгә, хак сүзгә бик сусаган булып чыкты, алар Асылгәрәй картның һәр сүзен күңелләренә сеңдереп бардылар, әйткәннәрен көнкүрештә кулланырга тырыштылар. Алар өс-башларын, ризыкларын, күңелләрен тәртипкә китерделәр, тормышларын һәм үзләрен булдыра алганча ислам кысаларына кертергә тырыштылар. Иң мөһиме — аларның динне өйрәнергә һәм исламча яшәргә теләкләре бар иде. Һәм аларны өйрәтергә әзер торучы юлаучы карт бар иде...

Әмма карт өчен тагы да мөһиме — боларның барысын да, хәтта артыграгын да хуҗабикәнең улы Сәүбәнгә өйрәтеп калдыру иде. Азан-намаз тәртибен дә, җеназа, мәет белән бәйле эшләрне дә ул — авылдагы бердәнбер ир-ат белергә һәм башкарырга тиеш иде. Ни хикмәт, Сәүбән бик зиһенле, тырыш бала булып чыкты, картның һәр сүзен, һәр гамәлен күңеленә сеңдереп, артыннан кабатлап барды. Әнисенең өйрәтүе буенча, намаз догаларын, аның тәртибен ул инде кечкенәдән белә икән, ә калганнарын аңа Асылгәрәй карт көне-төне өйрәтте. Сәүбән аны яратып бу яклар гадәте белән карттай дип атый, ягъни карт атай, бабай. Ул — Сәүбәннең үз гомерендә авылларында беренче күргән ир-аты, чөнки аның этисен дә, бабасын да ул әле әнисе карынында вакытта ук әллә аклар, әллә кызыллар атып чыгып киткән. Алар авылда бер ир-атны да калдырмаганнар. Шуңа күрә ул Акбулатта бердәнбер ир-ат...

Асылгәрәй карт та бу авылга очраклы рәвештә килеп чыкмавына ышана. Димәк, аның биредә туктавы тәкъдирдә үк каралган булган...

Аның тәкъдирендә шушы авыл халкын дингә өндәү язылган булган. Әмма язмыш аны бу авыл, бу кешеләр белән алга таба да бәйлисен Асылгәрәй карт үзе дә, башкалар да белми иде әле.

Аның кабере биредә буласын да, алга таба нәселе шушы авыл белән бәйләнәсен дә беркем белми иде.

Картны ерак сәфәргә бөтен авыл әзерләде. Халык бу галим картка инде тәмам ияләнеп беткән, аны бер дә биредән җибәрәселәре килми иде. Чөнки авыл халкы аксакаллар сүзенә, алар киңәшенә бик мохтаҗ, ятим хәлдә иде. Әмма Асылгәрәй картка да юлга кузгалмыйча булмый, аның Урал таулары арасына язмыш таратып ташлаган гаиләсен яңадан җыясы бар. Ул аларга кирәк, бик кирәк...

— Көтеп тора торган гаиләң булмаса, без синең монда

гына калуыңны сорар идек, — диде Кафия карчык, аны юлга әзерләп. — Авылда үзең теләгән хатынны никахлап алыр идең. Синдәй затлы кешегә теләсә кайсысы барыр иде. Менә Сафия да җиләк кебек хатын, ул сиңа үлгәнче тугры хезмәт итәр иде... Баласына ата булыр идең. Әмма үз гаиләңнең, балаларыңның хәле билгесез шул, бүген син аларга кирәк...

Асылгәрәй карт мондый сөйләшүне көтмәгән иде...

— Рәхмәт, Кафия абыстай, бу сүзләреңә, — диде ул. — Әлбәттә, Сафия да, бу авылның башка хатын-кызлары да кадер-хөрмәткә лаек. Әмма һәркемнең үз тормышы, үз язмышы маңгаена язылган шул. Минем өчен дә гаиләм, хатыным изге, нинди хәлдә дә мин аларны калдыра алмыйм. Рәхәт вакытларда бергә булдык, инде авырлыкларны да бергә күтәрик...

Шулай итеп, Асылгәрәй картны сәфәргә бөтен авыл әзерләде...

Кемдер җайлы өс-баш китерде, аяк киеме бирде, итен-ипиен, кипкән җиләк-җимешен әзерләде. Картка күтәрергә җиңел дә булырга тиеш, өенә кайтып җиткәнче, ашарына да җитәргә тиеш иде. Өс киеме дә җылы һәм җайлы булырга тиеш. Сәүбән аны Агыйдел буенча бераз озата төшә дип килештеләр. Алар башта Агыйдел буйлап көймәдә төшәчәкләр иде, аннан соң Асылгәрәй карт ялгыз гына китәчәк. Сәүбән Урал аръягына кадәр озата барам, дисә дә, Асылгәрәй карт моның белән килешмәде, баланың тормышын куркыныч астына куясы килмәде.

Иртәгә китәсе дигән көнне, җомга турында, Асылгәрәй карт, бөтен авылны җыеп, урман аланында намаз укытты...

Инде җәйнең көзгә авышып барган алтын бер чоры иде...

Урман да инде җәйдәге кебек ярсып шауламый, моңсуланып, тынып калган. Тау битләре дә шактый шәрәләнә, ачыла төшкән, чөнки анда яфраклар иртәрәк коела, үлән иртәрәк корый. Кояшның да җылысы сүрелә төшкән, тау араларына, үзәнлекләргә хәтле килеп тә җитми. Аның каравы җилгә гайрәт кергән, Урал тауларына инде ул хуҗа булып бара. Тиздән ул бирегә яңгыр болытларын куып китерер, яңгырга ияреп, кары ява башлар, боз төшәр. Урал тауларына бик озакка салкын кыш килер...

Аңарчы ныгып, аякка басып, тернәкләнеп калырга кирәк...

Котырып искән җил-давыллар да кузгатырлык, аяктан егарлык булмасын...

Әнә алар, кыйбла якка карап, бөтен авыл белән намазга басканнар...

Алда — юлаучы карт Асылгәрәй мулла...

Анын артында — бу якларда динне дәвам итәчәк Сәүбән бала...

Алар артында — татар хатын-кызлары...

Алар, урман аланына ак җәймәләр җәеп, Асылгәрәй карт артына басып намаз укыйлар. Бу дөньядан газап белән киткән уллары, аталары, бабалары, ир туганнары өчен дога кылалар. Аллаһтан үзләрен, балаларын, бу авылны, татар милләтен саклавын сорыйлар...

Аларның догалары җиде кат күкләргә барып ирешә һәм мәңгелеккә теркәлеп куела.

Иншаллаһ, моннан соң бу җирдә иминлек булыр...

Иншаллаһ, аларның кыз балалары, башка җирләрдә мөселман-татарларга кияүгә чыгып, нәселне саклап калырлар...

Иншаллаһ, алар белән бергә бу якларга яңадан дин кайтыр, алар кара урманнар уртасында да татар булып, мөселман булып яшәүләрен дәвам итәрләр...

Иншаллаһ, аларның догалары белән Урал тауларында татар халкы мәңге яшәр...

Икенче көнне бөтен авыл Асылгәрәй картны каекка утыртып, озатып калды. Сарбай анын аяк очына тын гына сузылып ятты, ул тагы ерак юлга чыгуларын аңлый иде. Сәүбән көймәне җай гына Агыйдел уртасына таба борды, һәм алар йөзеп төшеп киттеләр...

Хатын-кызлар яр буена тезелеп басып, кул болгап озатып калдылар. Акбулат авылы борылышта юкка чыкты, анын урынын тагы кыя-таулар басып алды...

Агыйдел буйлап шактый озак төштеләр алар...

Әле стена кебек басып торган текә кыялар яныннан ышкылып диярлек узып киттеләр, әле атылып киң үзәнлекләргә барып чыктылар. Асылгәрәй карт бу күренешләргә хәйран калып карап барды. Кыя-тау араларында Агыйдел гаять тарайды, тирәнәйде, үзәнлекләрдә бөтенләй җәелеп китте, төбе күренә башлады. Анда-санда яр буйларында, калкулыкларда авыллар сибелеп калды, болынлыкларда малларның тыныч кына утлап йөргәннәре күренде. Әйтерсең лә дөньяның асты өскә килмәгән, каядыр төрмәләр, сөрген дә юк, халыкны талаучы яңа власть та юк. Әйтерсең лә татарлар, борынгы заманнардагы кебек, монда тыныч кына яшәп яталар...

— Биредә гел татарлар яши, шуңа күрә мин бу якларга курыкмыйча төшәм, — диде Сәүбән, тирә-якка күрсәтеп. — Әнә, карттай, яр буендагы авылларны күрәсеңме? Әнә Сөбханкул, Ишбулат авыллары, әнә Миндәгол, Киекбай күренеп тора. Кафия әбинең сөйләвенчә, бу тирәдәге татар авыллары Нух пәйгамбәр заманыннан бирле яши икән. Шулай ук без-

нең авыл да. Кайбер татарлар мондагы авылларга Казан урыслар тарафыннан алынгач килеп урнашканнар икән, ягъни мондагы татарларга килеп сыенганнар. Минем үземнең Казанны күргәнем юк, әмма безнең нәселне Казаннар дип йөртәләр. Карттайны — Казан карты дип, картнәйне Казан карчыгы дип йөрткәннәр, әни шулай ди.

— Иншаллаһ, Казанны да күрерсең әле, улым, башкасын да, дөнья гел болай бармас, — диде Асылгәрәй карт, Сәүбәннең күп белүенә куанып. — Татар тарихы әле ул бер Казан белән генә бетми, улым, Кырымнарга, Кавказларга хәтле сузыла... Себер, Әстерхан да татар иле, Сарытау, мишәр йорты да татарныкы, анда бүген дә безнең халык яшәп ята. Килер бер көн, милләт әле боларның барысын да күтәрер, искә төшерер, барысын да сөргендә черетә алмаслар...

Алар тын гына су өстенә карап бардылар...

Агыйдел елгасы да, Асылгәрәй карт кебек, ничәмә-ничә тау сырты үтеп, инде бирегә хәтле килеп җитә алган. Иң биек тауларның берсе булган Ирәмәлдән, аның Әвәләк сыртыннан башланып, кырык сыртны үтеп, ул татар урман-даларына килеп чыга. Агыйдел дә, Асылгәрәй карт кебек, кояш батышына карап бара. Аларның ил-җирләре бер...

— Әни әйтә, Урал тауларының ике ягында да татарлар яши, ди. Минем анда кадәр үк барып җиткәнем юк әле. Безнең Казан әби гел бер бәет әйтә торган иде, Уралтауның ике ягында аерылып калган татарлар турында. Син беләсеңме аны, карттай?

— Белмим шул, улым, безнең якларда бармы икән ул бәет? Исеме ничек дисең?

— Сак-Сок кошлары турында ул, кошка әйләнгән балалар турында...

— Сак-Сок бәете безнең якларда да бик билгеле, улым, аны белмәгән кеше юктыр. Ә менә аның Уралтауның ике ягында аерылып калган татарлар турында икәнлеген белми идем. Димәк, борынгыдан шулай булган...

Малай, нидер исенә төшерергә теләгәндәй, шактый вакыт Урал тауларына карап торды...

Колагында картнәенең моңлы тавышы яңгыраган кебек булды. Күңелендә Сак-Сок кошларының фаҗигале язмышы яңарды...

Малай ул бәетне тыңлаганда гел елый иде. Аңа урман-таулар арасында бәргәләнеп йөргән ул кош балалары бик кызганыч булып тоела иде. Алар бит кошлар түгел, ә каргалган кешеләр... Һәм алар беркайчан да очраша алмыйлар, кавышабыз һәм яңадан кешегә әйләнәбез дигәндә генә, араларына һәрвакыт биек тау кереп баса... Әнә шул Мәчем, Шүлгән таулары кебек...

«Сак» та «Сок» дип кычкырабыз,
Югалган бездән бәхет.
Ике арада тау буладыр
Кавышабыз дигән вакыт.

Таң атып, көн яктырса,
Арабыз ерак торды.
Беребез «Сак» дигәндә,
Беребез «Сок» кычкырды.

Ата-ана дөнья куйды,
Калдык без кошлар булып.
Ике якта мәңге калдык,
Йөзне яшь белән юып...

Сәүбән туктап калды. Аның керфек очларында әллә Идел суы, әллә күз яшьләре җемелди иде...

Бәлки, ул үзе туганчы ук атып үтерелгән әти-бабаларын, ир туганнарын күз алдына китергәндер, кара урманнарда атасыз үткән ялгыз тормышын уйлап моңайгандыр. Асылгәрәй картның да күз алдына төрле якка таратып ташланган үз балалары килеп басты, әйтерсең лә бу борынгы бәет алар турында да иде. Һәм бу фаҗигале сүзләр бөтен милләт турында иде...

— Шулай, улым, — диде Асылгәрәй карт, бераз тын гына баргач. — Монда сүз ана каргышы турында гына бармый, монда сүз тәкъдир каргышы турында да бара кебек. Заманында ниндидер ялгышлар җибәргән өчен милләт балалары тәкъдир тарафыннан каргалган, ахры. Адәм үтә алмаслык таулар артына таратып ташланган. Һәм алар бүгенге көнгә хәтле кавыша, берләшә алмыйча тилмерәләр. Бик гыйбрәтле бәет бу, узганнар турында булса да, бүгенгегә дә карый, киләчәкне кисәтә...

Ул арада Агыйдел кинәт кенә борылды да туп-туры кояш батышына таба агып китте. Әйтерсең лә туган як үзе ашыгып Асылгәрәй карт каршына килә иде. Моны күргәч, картның сулышлары җиңеләеп китте, көймәдән төшеп, җәяүләп шул якка торып йөгерерлек булды. Әмма каршында гаскәр кебек биек таулар басып тора иде.

— Әнә каршыдагы иң биек таулар — Үтәмеш һәм Яман-тау сыртлары, — диде Сәүбән. — Әнә уң якта Мәчем белән Шүлгән кала. Ары таба Олытау, Шарлык, Канчак, Кыбыз, Әзгәрлән, Башалатау... Көмәч, Уйташ, Әвеш, Бәйгетау... Айгыртау, Бурлытау, Каратау...

— Шулхәтле күпме? — дип сорады Асылгәрәй карт, борчылып тирә-ягына карап.

— Күп әле, карттай... Әмма син борчылма, алар арасында үзәнлекләрдә сукмак булырга тиеш, биредәге халык шуннан йөри ар якка. Кыргый хайваннар юлы ул, һәм шулай ук

атлы сугышчылар юлы да булган. Син курыкма, монда теге кыргый кабиләләр юк инде, алар Агыйделнең бу ягына чыкмыйлар, теге якта җир куышларында яшеренеп яталар...

— Аллага тапшырдык инде, улым, — диде Асылгәрәй карт, үзләрен бөтен яктан да чорнап алган биек тауларга карап. — Моңа кадәр юлны исән-сау үттем бит, иншаллаһ, алдагысын да кичәрбез. Яңгырлар гына башланмасын, коры чакта илгә кайтып җитәргә язсын...

Көймә шуып кына киң үзәнлеккә килеп туктады. Иртәниртүк юлга чыксалар да, шактый ара үтелгән, һәм көн дә инде кичке якка авышып бара иде. Инде Сәүбәнгә кире кайтып китәргә кирәк, тау араларына тәмам караңгы төшкәнче, ул авылга кайтып җитәргә тиеш. Асылгәрәй картка да төнгә каршы юлга кузгалмавы хәерле, Сәүбәннең әйтүенчә, бу тирәдә тау куышлары бик күп икән, шунда кереп кунар...

— Уң кул яктагы менә бу Шүлгән тавында бик зур куыш бар, бүген шунда кереп йокла, карттай, — диде Сәүбән, шул якка күрсәтеп. — Соңгы сугыш вакытында анда дүрт йөз кешелек атлы гаскәр качып яткан, дип сөйлиләр, шундый зур ул. Картнәй аны бик борынгы, дип сөйли иде, Нух пәйгамбәр заманнарыннан калган, дип... Туфаннан соң беренче кешеләр шунда качып яткан икән... Анда әле стенага ясалган рәсемнәр дә бар. Анда төннәрен зур, алып кешеләрнең рухлары йөри, ди. Иркенрәк вакыт булса, мин дә синең белән калыр идем, хәзер кайтырга кирәк, карттай. Сау бул, исәнсау кайтып җит... Безгә тагы кил... Бөтенләйгә яшәргә кил, бабай...

Алар ата белән бала кебек кочаклашып аерылыштылар...

Бу вакыт эчендә алар бер-берләренә бик ияләнгәннәр, якынайганнар иде...

Ата назын күрмәгән Сәүбән өчен ул карттае булды...

Асылгәрәй карт өчен Сәүбән үз балаларын алыштырды...

Аллаһның тәкъдире белән, еллар үткәч, алар әле тагы очрашачак, иң якын кешеләр булачак иде...

— Динне, намазларыңны онытма, улым, — диде карт, Сәүбәнне кысып кочаклап. — Син авылда бердәнбер ир-ат, хәзер диннең рәтен беләсең, үзең дә тот, халыкны да шул юлдан чыгармаска тырыш... Акбулат халкы бик әйбәт, ипле халык, шәт, шушы юлдан барырлар... Насыйп булса, күрешербез, иншаллаһ, сез хәзер миңа туганнарым кебек якын...

Аннан ул кесәсеннән кечкенә бер төен чыгарды, аны малайга сузды.

— Моны бик кирәк вакытта гына тотарсың, улым, кирәгеңә файдаланырсың, — диде ул, төенчекне малайның учына салып.

Сәүбән төенчекне чишеп җибәрде...

Анда, баеп барган кояш нурларында сәер ялтырап, алтын бөртекләре җемелдәшеп ята иде...

— Үзеңә кирәк булыр бит, карттай? — диде Сәүбән, бу хәтле байлыкны алырга да, алмаска да белмичә.

— Үземә дә кала, улым, борчылма. Алла биргән байлык бу, барыбызга да җитә...

Инде аерылыр вакыт та килеп җитте...

Сарбай да инде Сәүбәнгә ияләнеп беткән иде, аннан аерыласы килмичә, көймә артыннан яр буйлап шактый чабып барды ул. Ул әле таулар арасында ялгыз басып торган Асылгәрәй картка, әле Агыйдел буйлап йөзеп киткән Сәүбәнгә карады. Кайсы белән барырга, кайсы белән калырга белмичә аптырады. Текә яр буена утырып, күккә карап бер улады да, китеп барган яшь дустына карап үксеп бер елады да Асылгәрәй карт ягына карап чабып китте. Ул аның берьялгызын ярты юлда ташлап китә алмый иде... Һәм Сарбай карт хуҗасы белән калырга уйлады... Ул арада, борылышка кереп, Сәүбән дә күздән югалды.

Асылгәрәй карт бүген юлын дәвам итмәскә булды...

Сәүбән әйткәнчә, ул төн кунарга тау куышына керде.

Тау куышы, чыннан да, искиткеч зур, бөтен авылың сыеп бетәрлек иде. Бәлки, монда заманында чыннан да авыл булгандыр, борынгы кешеләр бозлык чорын шушында качып уздырганнардыр. Мәгарә эчен җанландырып челтерәп чишмә агып ята, эчәргә, юынырга су аяк астында гына. Ул су тау куышы алдында күлләвек булып җыела да инеш булып Агыйделгә барып төшә. Ә Агыйдел әнә янәшәдә генә чайкалып агып ята. Биредә бөтен елгалар да Агыйделгә барып чыга, бары тик Агыйделгә генә коя. Ә Агыйдел, нәкъ Асылгәрәй карт кебек, Чулман-Иделгә ашыга. Аңа инде ерак та калмады, шөкер, юлның күп өлеше үтелде инде...

Бу уйларыннан Асылгәрәй картка җиңел булып китте...

Ул, ни әйтсәң дә, инде дөнья читендә түгел иде...

Менә бу таулар буйлап тагы бераз атларга да, тагы бераз түзәргә дә, һәм ул аргы якта булачак... Ә анда инде — тоташ үзәнлекләр, яхшы тигез юллар, кешеләр. Уралны үткәч, туган якларына кадәр ул поездда да кайта ала, чөнки анда инде болай тикшерү булмаячак, иншаллаһ. Аның әле юллык акчасы бар, кирәк икән, алтыны да бар, әмма ул алтынын ашыгып чыгармас. Ашарга җитәрлек, Аллага шөкер, авылда юл кешесенә ни кирәген бик белеп тутырдылар. Инде хәзер, сабырлык белән, кояш батышына карап атларга да атларга...

Бәхетенә, картның яралы җилкәсе дә инде авыртмый, җә-

рәхәте җөйләнгән, сөякләре ныгыган, арык тәненә ит кунган иде. Акбулатта аны, чын мәгънәсендә, яңадан аякка бастырдылар, яңа тормыш, яңа сулыш бирделәр. Мондый беркатлы, ихлас, изге кешеләр тау араларында гына калгандыр инде, мөгаен. Тормышларында нинди зур фаҗигаләр кичерсәләр дә, сынмаганнар, явызланмаганнар, кеше булып калганнар. Соңгы вакытта үз тормышын басып киткән авырлыклардан, кайгы-хәсрәттән Асылгәрәй карт үзе дә төшенкелеккә бирелә башлаган иде, Акбулат халкы белән очрашкач, яңадан терелеп киткән кебек булды. Шөкер, тормыш гел карадан гына тормый икән әле, кара урманнар уртасында булса да яктылык бар икән, ачык йөзле кешеләр калган икән. Димәк, яхшылыкка өмет бар дигән сүз.

Чишмә суы белән тәһарәтен яңартып, Асылгәрәй карт кичке намазын укып куйды. Аннан тау битеннән ылыслы ботаклар җыеп керде, аларны түшәк итеп җәеп, җайлап йокларга ятты. Сарбай да, элеккеге гадәт буенча, мәгарә ишеге төбенә сузылып ятты. Аңа хәзер хуҗасын саклау бурычы йөкләнгән иде. Һәм ул монда ятканда, бирегә җан иясе үтеп керерлек түгел иде.

Асылгәрәй карт, кыйблага карап яту белән, тирән йокыга китте. Шуны гына көтеп торгандай, аның җанына хатирә-хәбәрләр иңә башлады...

Әллә җан, тәннән вакытлыча чыгып китеп, үз дөньясында гизә иде, әллә картка күктән төш-хәбәрләр иңә — аңларлык түгел.

Ул Зәйтуган авылын да, Урал тауларын да, Җаек далаларын да — барысын берьюлы күрә. Барлык балалары, гаиләсе, үткәннәре һәм киләчәге — барысы берьюлы аның күз алдыннан үтә.

Томан арасыннан үзенә таба атлап килүче кайбер кешеләрне карт инде үзе дә танымый, кайбер вакыйгаларны белми, чөнки әле алар аның тормышында булмаган, әмма булачак...

Бу кешеләр, бу вакыйгалар башка дөньядан, башка тормыштан.

Әнә Җаек суы буенда, текә ярда зур утар...

Утарда ике катлы таш йорт, аның тирә-ягы гөлләр-чәчәкләр белән тулы, дала уртасында ямь-яшел агачлар шаулап утыра. Шул гөлләр арасында ак яулыклы бер карчык йөри... Тукта, бу йорт аның Зәйтугандагы өенә бик охшаган бит, ак яулыклы хатын Мәһинур абыстай кебек... Әмма ул да түгел. Аның нурлы йөзендә кызы Мәрзия чалымнары бар, әмма ул бала иде бит әле... Аның янында ак чәчле мөлаем карт. Кем соң ул? Аның йөзендә Сәүбән чалымнары бар,

әмма ул да үсмер бала гына иде бит әле. Алар янында Асылгәрәй картка һәм Маһинур карчыкка охшаган балалары, оныклары — зур, ишле нәсел...

Әнә Җаек елгасы буенда күккә биек манара күтәрелә, аның көмеш ае болытлар арасына кереп югалган. Асылгәрәй картның әле беркайчан да мондый зур һәм матур мәчетне күргәне юк иде. Һәм мәчетнең эче-тышы аның нәселе белән тулган... Әнә ап-ак чәчле Солтанхәким азан әйтә, аның артында балалары, оныклары сәҗдәгә тезләнгән... Әнә Гайшәнең балалары һәм оныклары, Равилнекеләр дә монда, Сабиранықылар да килеп җиткән. Аллаһъяр хәзрәт оныклары, Әхсән мулла балалары, Габдрахман хаҗи нәселе. Сөргенгә сөрелгән татар муллаларының зур нәселе, таш-тимер арасында зур мәчет төзеп, бер Аллага табыналар, үле далада да дин-исламны дәвам итәләр.

Карт бу урынны, бу шәһәрне таный да, танымый да.

Еракtan, күгелҗем томанга уралып, Урал таулары күренеп тора.

Дала белән таулар арасына Җаек елгасы сузылып яткан.

Һәм аста — тоташ таш шәһәр, тимер патшалыгы...

Күк йөзенә йөзләгән утлы кара торба төбәлгән.

Домна мичләренең тоташ ялкыннан җирдә кар эри, күктә кояш томалана...

Алар, көне-төне уһылдап, тимер эретәләр, чуен коялар.

Аларның нигезендә кеше сөякләре агарып ята...

Бу таш шәһәр һәм тимер гиганты кеше сөякләре өстенә салынган...

Сөргенгә сөрелгән йөз меңләгән татарларның көче белән һәм аларның сөякләре өстенә...

Асылгәрәй картның балалары да шунда ята...

Әнә кулына бер уч чирәм тотып тезләнеп үлгән Сәгыйте...

Кирпеч астында калып сытылып үлгән Саҗидәсе...

Сөрген юлында тифтан үлеп калган төпчеге — Рәйсәсе...

Җаек суыннан агып төшеп барган Гыйлемгәрәе...

Аларның җаннары менә ничә еллар, буш далага төшеп, дога көтеп йөргән.

Менә хәзер бөтен нәсел, кыйблага карап, сәҗдә кыла, намаз укый, әрвахлар рухына багышлап дога кыла.

Асылгәрәй хәзрәтнең ачтан үлгән балалары дога белән мәңгегә азыклана...

Асылгәрәй хәзрәт шушы ишле нәсел арасыннан үз хәләлен — Маһинур абыстайны эзли. Ләкин ул анда юк. Картның җаны, моны күреп, үзенә урын таба алмый, Урал таулары арасында бәргәләнә башлый.

Ул Урал тауларының әле бер ягына, әле икенче ягына атыла. Менә ул Зәй буйларыннан очып уза, атылып Зәйтуган авылына килеп керә, үз нигезенә килеп тезләнә. Һәм туган туфракка капланган Маһинур абыстайны күрә. Ул бик бетеренгән, яшәү белән үлем арасында басып тора, шул чиктән үтеп бара. Әмма ул Асылгәрәй хәзрәтне күрмичә китә алмый. Инде күктән, рәт-рәт булып тезелеп, фәрештәләр төшеп килә, җигүле ак ат рәвешендә ак болыт көтеп тора. Маһинур абыстай, шуңа утырып, инде мәңгелеккә китәргә тиеш икән. Моны күреп, картның җаны яңадан Урал тауларына атыла. Ул тәнгә килеп керә, картны сискәндереп уята, үзе белән өнди, үз артыннан чакыра...

Карт әсәрләнеп күзләрен ача.

Аяк астында чишмә челтерәп агып ята.

Тау куышына сирпелеп кенә таң яктысы кереп килә.

Тышта әллә кошлар сайрый, әллә җил шаулый, әллә кемдер үксеп елый.

Бу Асылгәрәй картның күпне күргән җаны шулай сулкылдый, ахры...

Аның күз алдыннан төнлә күргән төше китмәде. Әле хәләле, әле балалары хәтере буйлап үтеп киттеләр. Җаек буйларындагы зур мәчетне күреп, карт куанды, нәселенең анда динне саклап каласын белде. Аллаһы Тәгалә аңа бик хикмәтле нәрсәләр күрсәткән иде. Аның балалары исән, һәм алар бу җирләрдә мәчетләр торгызачак иде. Төшендә ул аларның шушы иманлы киләчәген күрде...

Әмма ул төшендә яшәү белән үлем чиген үтеп баручы хатынын да күрде.

Ул инде туган туфракта һәм шунда мәңгегә калырга әзерләнә иде.

Ул китеп өлгергәнче, Асылгәрәй карт Зәйтуганга кайтып җитәргә тиеш иде.

Шуны сорап, карт иртәнге намазыннан соң Аллаһка дога кылды.

Аларга бер-берләренең бәхиллекләрен алып калырга кирәк иде...

Ул кояш белән юлга кузгалды. Аның бәхетенә, көннәр әле матур тора, аяк асты коры, сукмаклар салынган иде. Сәүбән дә аңа кай тарафка барырга кирәклеген яхшылап өйрәтеп калдырды. Хәер, карт үзе дә инде бу кырыс тауларга иярләнеп бара, аларның тәртибен белә, әйтерсең лә гомер буе алар арасында яшәгән. Ул хәзер аларның рәвешләреннән аңлый, яшерен сукмакларны бер карау белән таный, кояшка, җиргә, җилгә карап, барыр юлын билгели ала. Сарбай да үз

эшен белеп эшли, бер алдан, бер арттан йөгерә, карт янына бер җан иясен якын җибәрми, көне-төне саклап бара. Тауларда исә ул гел алга чыга башлады, карт яшерен сукмаклар буйлап аның артыннан барды. Урал тауларының бу ягы шактый тыныч, анда селәүсен кебек ерткыч җанварлар да, кыргый кешеләр дә очрамый иде.

Шулай итеп, кайда тау куышларында, кайда елга буйларында кунып, алда торган тау сыртларын исән-сау үтеп, алар тагы берничә көн бардылар. Менеп булмас кебек күренгән Үтәмеш, Капчак, Кыбыз, Ямантау сыртлары инде җиңелеп артта калды. Алардан соң инде таулар тәбәнәкләнә башлады, гүя алар да, адәм баласының бернигә карамастан ярсып алга атлавына тетрәнеп, аның алдында тез чүккәннәр иде. Гүяки бу таулар да аңладылар — кеше барыбер үз дигәненә ирешәчәк, барыбер алар аша үтәчәк иде. Һәм шулай булды да...

Ниһаять, таулар җиңелде, таулар чигенде, таулар бетте. Алда иксез-чиксез тугайлыклар җәелеп ята иде.

Карт кырык сыртны үткән иде...

Аның алдында Әлмәт-Бөгелмәләргә кадәр җәймәдәй тигез җир җәйрәп ята иде.

Карт соңгы тауның итәгенә килеп утырды. Көзге йомшак җил аның ак чәчләрен сыйпап үтте.

Кояшның җылы нурлары картның йөзен иркәләде.

Җир аның арыган аякларына, тәненә ял бирде.

Чишмә суы сусавын басты, җанын тынычландырды, көчгайрәт өстәде.

Бар табигать аның каршында олылап баш иде.

Карт бүген җиңүче иде.

Ул тауларны, тау кебек авырлыкларны җиңгән иде.

Һәм исән калган иде.

Һәм боларның барысы өчен дә ул бер Аллаһка рәхмәтләрен әйтеп дога кылды...

Инде хәзер калган юлны дәвам итәргә кирәк иде...

Әнә Сарбай да, шуны аңлагандай, картның аяк очына килеп утырган. Алар, барысын да аңлагандай, шактый вакыт бер-берләренә карап тордылар. Асылгәрәй карт алга таба башка юлдан китәчәк иде. Ул инде калган юлны җәяүләп үтмәс, поездга чыгар, иншаллаһ. Ул, бик теләсә дә, Сарбайны үзе белән ала алмас. Ул аны кире тауларга — үз дөньясына җибәрер. Сарбай — адәм баласы кебек акыллы җан иясе, нишләргә кирәген үзе белер. Теләсә, тауларда калыр, теләсә, Акбулатка Сәүбән янына кайтыр. Инде аларны кыргый кешеләрдән саклар, авыл халкына тугры хезмәт итәр...

— Бар, Сарбай, тауларыңа кайт, — диде карт, күз яшьләрен күрсәтмәскә тырышып. — Син барыбер бүреләр нәселеннән бит, биредәге коллыкны күтәрә алмассың...

Сарбай, картның сүзләрен аңлагандай, соры күзләрен текәп, аңа озак карап торды. Аннан кинәт кенә борылды да әкрен генә таулар ягына таба китте. Башта ул салмак кына барды, аннан йөгерә үк башлады, әйтерсең лә ул аерылу авырлыгыннан тизрәк качарга тели иде. Менә ул ике араны аерып торган соңгы тау сыртына чабып менде, соңгы тапкыр түбәнгә, Асылгәрәй карт басып торган үзәнлеккә карады. Карт та, урыныннан кузгалмыйча, аңа карап тора иде. Сарбай биек кыя башыннан күккә карап үксеп улап җибәрде. Үзәк өзгеч бу тавышта юлаучы карт белән бәхилләшү авазлары да, тауларны җиңү тантанасы да, аерылу ачысы да чагыла иде. Бу дәһшәтле һәм фаҗигале тавыштан таулар тетрәде, кош-кортлар качты, тирә-як шомланып тынып калды. Чөнки алар аңлады, бу тау бүресе тавышы иде. Чөнки Сарбай урам эте түгел, тау бүресе иде. Һәм биредә ул хуҗа иде.

Бөтен дөньяга, шул исәптән Асылгәрәй картка да шуны аңлатканнан соң, Сарбай кинәт кенә борылды да ук булып сыртның аръягына атылды. Алда аны җәйрәп яткан Урал таулары, аның адәм үтә алмаслык кырык сырты, үз дөньясы көтә иде. Һәм ул шуларның каршына иректә җил булып атылды. Тау араларында йөреп туйгач, бәлки, ул яшь дусты Сәүбән янына кайтыр, бәлки, карт хуҗасы эзләре буйлап китеп барыр. Әмма ул хәзергә таулар иркендә, Уралтау кочагында патшалык итәчәк. Аларга үзенең тау бүресе икәнлеген исләренә төшерәчәк...

Ә Асылгәрәй картны киң үзәнлекләр көтә.

Сары иген кырлары, яшел тугайлыклар, бөдрә таллы әрәмәләр, куе урманнар — туган як көтә.

Аны алда Зәйтуган көтә, хәләле Маһинур абыстай көтә. Чөнки бу дөньяда һәркемнең үз юлы, үз дөньясы, үз тормышы иде...

* * *

Капка артында тавыш көчәйгәннән-көчәя барды.

Өйдәгеләр барысы да уянды, күңелләрен хәвеф һәм борчу басты. Әле барысында да нindидер яшерен өмет бар иде, Шайтан Шакир эчкән баштан гына котырып алыр да туктар, карчык кеше белән бәйләнеп йөрмәс дип уйлаганнар иде. Нindидер могҗиза булыр да, Маһинур карчыкка кагылмас-

лар, монда калыр дип өметләнгәннәр иде. Алай булып чыкмады. Таң белән инде капка кагалар. Тавышка Гарифҗан кияү киенеп чыкты.

Авыл советы каравылчысы килгән икән, Шайтан Шакир карчыкка әзерләнеп идарәгә килеп җитәргә кушкан. Инде атлар җигелгән, озатучылар Мәһинур абыстайны көтеп торалар икән. Шайтан Шакир: «Бернинди саботаж булмасын, юкса бөтен гаиләләре белән төяп озатам», — дигән, тиз арада җыенырга боерган.

Бу хәбәрне көтсәләр дә, аны ишеткәч, өйдәгеләр кара кайгыга төштеләр. Ничек инде үләргә торган карчыкны юлга чыгарасың, төрмәгә озатасың? Бу мөмкин хәлме, була торган эшме? Сабира ничек үз анасын үз куллары белән шулай биреп җибәрә алсын? Ул аның урынына үзе Себер китәргә әзер, тик әнисенә генә кагылмасыннар. Сабира анасын кочып үксеп елап җибәрде. Ул арада балалар уянып мышкылдап елый башладылар, өйдә ыгы-зыгы купты. Бары тик Мәһинур карчык кына тыныч иде. Ул кызы Сабираны да юатырга тырышты:

— Борчылма, кызым, тәкъдирдә ни язган булса, шуны күрербез, — диде ул, әкрен генә өс-башларын киенеп. — Әтиең генә кайтып өлгерә алмады. Гел кайтып керер кебек, күңелем гел шуны көтә...

Аның бу сүзләренә каршы берни дә эндәшмәделәр. Чөнки кайтып керсә, Асылгәрәй картны да шушы ук хәл көтәсен беләләр иде. Шайтан Шакир хәзер аны козгын кебек каравыллый, көтә, кайтып керсә, тотып алып, шунда ук кире сөрәчәк. Ул хәзер бу нәселгә талпан кебек кадалды, каннарын эчеп бетермичә туктамаячак. Аннан ерак булуың хәерле иде.

Мәһинур карчык юлга үзе белән берни дә алмады. Әйтерсең лә аларның инде кирәк булмаячагын белә иде...

Ул чиста өс-башын киде, тәһарәтен яңартып, иртәнге намазын укып алды. Ул үзенең яңадан сөргенгә сөреләсенә, яңадан төрмә юллары үтәсенә һаман ышанып бетми иде. Күз яшьләре белән бергә кушып, иртәнге чәйне эчкәч, юлга кузгалдылар. Аларга мәчет урамына, үзләренең элекке нигезләренә, хәзерге идарәгә барырга кирәк иде. Сабира чайкалып торган әнисен култыклап алды, Гарифҗан кияү кечкенә төенчеген тотты, балалар елап арттан иярделәр. Бу хәлне күреп, күрше-күлән капкадан чыкты, эшнең нәрсәдә икәнен белгәч, барысы да аһ итте, елаша башладылар. Заманында Асылгәрәй хәзрәт белән Мәһинур абыстайдан белем алган авыл халкы, аларга карата бу хәтле явызлыкны күреп, телсез кал-

ды. Абыстайның яңадан сөрелү хәбәрен ишеткән кешеләр берәм-берәм мәчет урамына җыела башладылар. Зәйтуган халкы бу хәлләрдән бер дә риза түгел иде.

Менә Мәһинур абыстайларның төп нигезләренә дә килеп җиттеләр. Ике катлы бу йорт хәзер колхоз кәнсәләре һәм авыл советы итеп үзгәртелгән иде. Аның инде элеккеге коты-яме киткән, ул буш, кызыл өндәмәләр белән тулган колхоз йортына әйләнеп калган. Ишегалдын тутырып үсеп утырган гөл-чәчкәләр дә юк, җәйге чәй эчү урыннары да җимереп ташланган, заманында сары ком сибелгән сукмакларны ат тизәге баскан. Мәһинур карчыкка дигән җигүле ат та инде монда тора, озата баручылар Бөгелмә төрмәсенә чыгып китәргә әзер. Барысы да Шайтан Шакирның килеп җитүен, әмер биргәнен көтәләр, ә ул иртәнге чәен эчәргә кайтып киткән...

Мәһинур абыстай, үзе белән мәңгелеккә алып китәргә теләгәндәй, йотылып тирә-якка карады. Зәйтуганны ул әйтерсең лә беренче һәм соңгы тапкыр күрә иде. Анда, сөргендә вакытта, көн дә төшләренә кереп тилмерткән Зәйтуган. Зәй суы буендагы ялгыз өянкеләр, бөдрә таллар, авылны җил-давыллардан ышыклап торган сөзәк таулар, тау итәгеннән башланып киткән куе урманнар, яшел әрәмәләр. Алар Җаек далаларында да аның күңел түрендә булдылар, бер генә мизгелгә дә исеннән чыкмадылар. Инде беттем, инде бу дөньядан бөтенләй киттем дигән чакларда да тотып калдылар, үзләрендә яшәттеләр. Һәм аны бирегә тартып кайтардылар...

Зәйтуган бүген аеруча моңлы һәм сагышлы күренә. Яңгырдан соң җирдән җылы пар күтәрелә, ул, ак томанга әйләнеп, әкрен генә авыл өстенә тарала. Инде яр буендагы таллар да, авыл читендәге таулар да күренми башлый, томан авыл өйләрен, урам-тыкрыкларны сарып ала, сузылып юлларга төшә. Әйтерсең табигать бу кара эшләрне ак томаны белән булса да каплап куярга, дөнья күзеннән яшерергә тырыша...

Карчыкның башы әйләнеп китте, һәм ул янындагы агачка тотынды. Асылгәрәй хәзрәт белән икәүләп утырткан алмагач иде ул. Аның инде алмалары юк, кәүсәсен хайван кимергән, ботаклары сынып, каерылып төшкән. Башкалары да шул ук хәлдә. Чөнки монда хәзер хайваннар хуҗа, шул исәптән ике аяклылары да. Абыстайның данлыклы гөл-чәчкәләре урынында шайтан таягы, әрем һәм кычыткан котыра. Боларны күрмәс өчен, Мәһинур абыстай әкрен генә үзенең элеккеге алма бакчасы буйлап китте. Каршысына шул ак томан-

нар арасыннан берәм-берәм балалары йөгереп килеп чыгарлар кебек тоелды. Равиле, Сабирасы, Гайшәсе, Гыйлемгәрәе, Сәгыйте, Саҗидәсе, Солтанхәкиме, Рәйсәсе, Мәрзиясе. Алар артыннан елмаеп ап-ак чәчле әтиләре — Асылгәрәй карт атлый кебек. Әйтерсең лә, кыя-тау булып, балаларны, гаиләне, Маһинур абыстайны бәла-казалардан саклап бара...

Шул арада арттан, ак томан эченнән, Шайтан Шакирның карлыккан кара тавышы ишетелә:

— Атлар әзер! Кузгалыгыз!

Бу куркыныч хәбәр авыл өстендә көзге яшен булып яшьни, кара кайгы булып күкри...

Кемдер кычкырып елый башлый, кемдер кычкыра, кемнедер гаеплиләр, кызганалар, каргыйлар... Томан эченнән ярсып кычкырган тавышлар ишетелә:

— Бирмибез абыстайны!

— Аннан кемгә зыян, ник тиясез аңа?

— Гөнаһысын кая куярбыз, Алла каршында ни дип җавап бирербез?

Зәйтуган халкы Маһинур абыстайны сырып ала, кемдер бәхилләшә, кемдер җибәрмәскә тырыша, юлына аркылы төшә. Ләкин монда Шайтан Шакир да бар бит әле, аның кулында камчы бар, теләсә кемне төрмәгә тыгып куярлык власть бар, Зәйтуганга хәзер тулысынча ул хуҗа.

Менә ул озак эчүдән күгәреп-карлыгып беткән тавыш белән авыл өстенә үкереп җибәрә:

— Үзегезнең дә Себер китәсегез киләме, хайваннар?! Бүген үк бу карчык артыннан шунда булырсыз! Мин сезгә күрсәтермен авылда ничек тәртип сакларга! Совет властена каршы барасызмы, контрлар?! Шушы кулак калдыклары сезгә кадерлеме?

Халык куркып артка чигенде...

Маһинур карчык ак томан эчендә берьялгызы басып калды.

— Ә син, кортка, утыр тизрәк арбага! — дип кычкырды Шайтан Шакир, бу эшне тизрәк тәмамларга ашыгып. — Кузгалыгыз, кузгал! Кузгал, дип әйттем бит мин! — Ул миңгерәеп басып торган Маһинур абыстайны бөтереп алды да арба төбенә ыргытты...

Аяк астында җир селкенеп куйды, күкләр ишелеп авыл өстенә төшә язды, Зәй суы агуыннан туктап калды...

Шул чагында Шайтан Шакирның үзен дә нindидер көч җирдән кубарып алды, һәм ул чәймәлеп ат тоягы астына барып төште...

Моны күреп, халык аһ итте, нәрсә булганын аңламый да калдылар.

Арбада, күккә карап, Мәһинур абыстай ята, ә аның өстенә Хозыр Ильяс кебек ап-ак карт иелгән иде... Зәйтуган уртасындагы нигезендә, ак томан арасында Асылгәрәй карт басып тора иде.

Ул арада пычрак арасыннан мүкәләп Шайтан Шакир да торып басты. Аның авызыннан кан ага, бите ат тизәгенә буялган, үзе нидер мөгри, кычкырына иде:

— Үтерәм, кулак тәре! Совет властена кул күтәрәсеңме монда кайтып?! Төрмәдә черетәм, юк, аттырам мин сине, нәселеңне корытам, җир белән тигезлим...

Ул арада томан арасыннан кемдер аңа тибеп җибәрде, кемдер тагы китереп өстәде, Шайтан Шакир тәгәрәп баскыч астына ук кереп китте. Һәм ул аннан яңадан күренмәде...

Ә Асылгәрәй карт боларның берсен дә күрмәде һәм ишетмәде. Ул Мәһинур абыстайның башын беләгенә салган да аның ирен читләреннән агып чыккан ал тасманы сөртә. Хәләленең зур булып ачылган күзләрендә ул үзенең чагылышын күрә, әйтерсең лә аның белән бергә үткән бөтен тормышын күрә...

— Мин синең кайтып җитәсеңне белдем, хәзрәт, — ди абыстай, телен чак әйләндереп. — Көттем. Әле ярый кайтып өлгердең...

Аннан ул, авырлык белән генә башын борып, тирә-якка карады. Ул гомеренең соңгы мизгелләрендә улы Солтанхәкимне эзли иде.

— Солтанхәким күренми. Әллә бер-бер хәл булдымы, хәзрәт?

— Борчылма, әнисе, ул исән, — диде карт, аны тизрәк тынычландырырга ашыгып. — Мин аны яхшы кешеләр янында калдырдым...

— Ә мин Гыйлемгәрәйне саклый алмадым, әтисе, — диде Мәһинур абыстай, авырлык белән тын алып. — Аны качканда ук атып үтерделәр... Кызлар исән булырга тиеш... Алар белән юлда аерылдык... Аларны тотып кире җибәргәннәр...

Карчык сүз әйткән саен, аның ирен читләренә ал тасма саркып чыга, ул күзгә күренеп сүнә бара иде. Әмма соңгы сүзләрен, балалары турында соңгы хәбәрне дә әйтмичә кала алмый. Ул бит хәзрәтен шуның өчен көтте... Карчыгының китеп барганын күргәч, Асылгәрәй картның аяк астында җир селкенеп куйды. Аның гомер иткән хатыны, балаларының газиз анасы бу дөнья читеннән инде үтеп бара иде...

Ул арада, нидер сизенеп, арба янына Сабира йөгереп килеп җитте, оныклар җыелышты, абыстай яткан арбаны авыл

халкы сырып алды. Барысы да бу хәлләрдән шашып калган иде... Мәһинур абыстайның соңгы мизгелләр кичерүен барысы да аңлаганнар иде...

— Балаларны сакла, хәзрәт, — диде Мәһинур абыстай, соңгы әманәте итеп. — Үзеңне сакла... Мин синнән риза-бәхил... Син дә бәхиллегеңне бир... Кичер...

— Бәхил, әнисе, мин синнән мең бәхил... Җәннәтләрдә очрашырга насыйп итсен, җаным...

Мәһинур абыстай аңа озак кына текәлеп карап торды. Ул инде әйтәсе сүзләрен әйтеп бетергән иде. Һәм аның тәкъдирдә язылган гомере беткән иде.

Аның соңгы теләге Зәйтуганны кайтып күрү иде. Аллаһ аның бу теләген үтәде, авылына исән-сау кайтарып җиткерде.

Аның соңгы теләге иренең бәхиллеген алу иде. Аллаһ аның бу теләген дә үтәде, аларны мәңгегә аерылыр алдыннан очраштырды.

Аның соңгы теләге Зәйтуган туфрагында күмелү иде. Аллаһ аның бу теләген дә үти, иншаллаһ...

Ул инде төрмә, сөрген газапларыннан да мәңгегә котылды, бу авырлыкларны ул инде беркайчан да күрмәячәк, кичермәячәк. Аны инде хәзер Зәйтуганнан беркем беркая куа алмаячак. Шушыларны уйлагач, карчык елмаеп куйды.

«Аллаһ — бөек. Ул ничек язган, шулай була» дип уйлап өлгерде...

Бу аның дөньялыкта соңгы уе иде...

Иреннәре исә «Ләә илаһә иллаллаһ» кәлимәсен кабатлады...

Бу аның дөньялыкта соңгы сүзләре иде...

Авыл өстеннән кыйбла якка таба ак болытлар йөзеп үтте. Бу Мәһинур абыстайның дөньялыкта күреп калган соңгы күренеше иде...

Ак болытлар аның күзләрендә туктап калдылар, күк йөзе һәм җир карчыкның соңгы карашына сыеп беткән иде...

Һәм ул бу күренешне үзе белән мәңгелеккә алып киткән иде...

Асылгәрәй карт әкрен генә аның күзләрен йомдырды. Җигелгән атны борып, Сабираларга алып кайтып киттеләр. Мәһинур абыстайны шушыннан соңгы юлга озатачаклар иде. Авыл халкы да ат артыннан иярде.

Баскыч астында Шайтан Шакир берүзе бөгәрләнеп ятып калды. Аның атлы арбаны кире борырга батырчылыгы җитмәде, мәет аннан көчлерәк булып чыкты. Ул хатынының үле гәүдәсе артыннан башын иеп атлаган Асылгәрәй картны да туктата алмады. Качкын мулла да аннан көчлерәк булып чыкты. Авыл халкы Шайтан Шакирга хәзрәтне тук-

татырга ирек тә бирмәс иде. Чөнки авылның үзенең язылмаган кануннары, яшәү тәртибе бар. Мәет кара җиргә кереп ятканчы, барысы да ул дигәнчә булачак. Һәм Асылгәрәй карт кем генә булса да — мулламы ул, каторжникмы — кайткан икән, хатынын үзе күмәргә тиеш иде. Бу вакытта башка законнар туктап тора, бары тик авылның, милләтнең йөз еллар буе яшәп килгән үз кануннары гына хакимлек итә башлый.

Маһинур абыстайны, кызы һәм күрше хатыннары җыелып юып, бала кебек ак биләүгә төрделәр. Аның тәненнән, йөзеннән нур түгелеп тора, ул яңадан элеккеге хәленә — Зәйтугандагы бәхетле чакларына кайткан иде. Әйтерсең лә ел буе сөргендә авыр газаплар күрмәгән, ачлык-авыруларны, югалту фаҗигаләрен белмәгән. Аның йөзендәге илаһи тынычлык башкаларга да тәэсир итте, алар карчыкның чит җирләрдә ятып калмавына, илгә кайтып үлүенә сөенделәр. Аның инде бөтен теләкләре үтәлгән иде, ул, кызы тарафыннан юылып, кәфенләнеп, Зәйтуган зиратына барып ятарга әзерләнә иде.

Зәйтуган зиратында карчыгы өчен каберне Асылгәрәй карт үзе казыды. Җеназаны да үзе укыды, кабергә дә үз куллары белән төшерде.

Маһинур абыстайны озатырга бөтен авыл халкы җыелган иде. Аның монда күмелүе Зәйтуганга бәхиллек бирүе, бәхилләшүе иде...

Икенче көнне Асылгәрәй картны, карчыгы өчен җигелгән атка утыртып, Бөгелмә төрмәсенә озаттылар. Төнлә авылга кораллы сакчылар килеп җитте һәм таң белән алып та киттеләр. Анда исә, хөкем итеп, яңадан Урал аръягына — Магнитка төрмәсенә җибәрделәр. Урал тауларының кырык сыртын, кулына богау киеп, ул яңадан мал вагоннарында үтте. Бу юлы инде берьялгызы үтте. Янында гомер иткән хатыны да, балалары да юк иде. Ул туган якларына мең газап белән әйтерсең газиз хатынын күмү өчен генә кайткан иде. Аның белән бәхилләшеп калу өчен ашыккан иде...

Ә анда, кырык сыртның аръягында, Җаек далаларында, аны башка дөнья көтә.

Төрмәләре, тимер торбалары, бозлы бараклары, җир асты куышлары белән аны Магнитка көтеп тора иде. Шул ук вакытта анда аны газиз балалары, үлгәннәренең каберләре, рухлары да көтә иде. Шулар хакына булса да ул кырык сыртны яңадан кичәргә, исән калырга, яңадан аякка басарга тиеш иде...

Аның гомер аты тагы Урал таулары аша үтеп бара иде...

* * *

Таш шәһәрдән шактый читтә, Җаекның текә ярында, бер утар бар. Көйгән соры далада ул яшел утрауны хәтерләтә, чөнки анда агачлар шаулап утыра, гөлләр чәчәк ата, чишмәләр челтерәп агып ята. Бу утарда берничә йорт та бар, алар берсеннән-берсе матур, бай һәм зәвыклы итеп эшләнгән. Капка-тәрәзәләрдә челтәрле бизәкләр, коймалар ялт итеп төрле төскә буялган, һәр бизәктә татар рухы ярылып ята...

Әйе, Җаек ярындагы бу утарда татарлар яши. Әнә ак яулыгын зурлап татарча бәйләгән бер карчык ишегалдындагы гөл-чәчәкләргә су сибеп йөри. Мәрзия абыстай ул, мәчет ачылышына барганчы, намаздан соң гөлләренә су сибеп калдыра. Бүген Магнитка шәһәрендә дөньяда тиңе булмаган мәчет ачылырга тиеш. Халык аны үз акчасына ун ел салды, төп чыгымны Асылгәрәй картның нәселе күтәрде. Һәм бүген алар бөтен дөньядан бирегә җыелдылар — Зәйтуганнан, Акбулаттан, Үзәнбаштан, Ташкенттан, Казаннан, Уфадан, Магнитканың үзеннән. Кунакларын алып, Мәрзия абыстай да тиздән шунда китәргә тиеш.

Мәрзия абыстай, әзерләнәләрме икән дигәндәй, күрше йортларга күз төшерде. Аларда да инде уянганнар, хәрәкәт башланган иде. Бу утарда алар бөтен нәсел бергә җыелып торалар — әнә Гайшә апасының балалары йорты, әнә Солтанхәкимнекеләр, менә Мәрзия абыстайларның зур йорты. Аларның йорты нәкъ Зәйтугандагы кебек — ике катлы, җиләк-җимеш бакчалы, гөлләр арасына күмелеп утыра. Әмма Зәй ярында түгел, Җаек ярында... Туган нигездән мең чакрым ераклыкта, далада...

Ул арада өйдән ире Сәүбән дә чыкты. Ул да инде ап-ак чәчле карт. Ә Магниткага килгәндә унбиш яшьлек үсмер малай иде бит...

Мәрзия әле дә хәтерли: әтисе Магнитка төрмәсендә өч ел ятып, алар янына чыккач, иң беренче эш итеп Солтанхәким белән Сәүбәнне бирегә китертте. Солтанхәкимне Тимербулат карт үзе китерде, алар соңыннан да Асылгәрәй хәзрәт белән гомер буе дус булдылар. Солтанхәким гомер буе аны карттай дип йөртте, Тимербулат карт та аңа үз баласына караган кебек карый иде. Сугыштан соң Тимербулат карт үлеп киткәч, Солтанхәким аны үз куллары белән юды, кәфенләде, җеназа укып җирләде. Һәм заманалар үзгәргәч, карттае хөрмәтенә Үзәнбашта мәчет тә салдырды, хәзер дә аны догасыннан калдырмый.

Мәрзия абыстай әле дә хәтерли: әтисе төрмәдән кайтыр

алдыннан, Аллаһъяр бабай инде мәрхүм иде. Гайшә апасы белән Самат җизниләренә баракта аерым бүлмә бирделәр. Әтисе дә төрмәдән шунда кайтып керде, ул ишле гаиләнең хуҗасы булды. Ул арада балалар бергәләп үсә тордылар, кайсы укырга керде, кайсы эшкә урнашты, кайсы армиягә китеп барды. Магнитка да инде үзгәреп, зур шәһәргә әйләнеп бара, монда эшкә керергә дә, укырга да мөмкинлекләр бар иде. Иң мөһиме — теләге булган кешеләргә заводлар янындагы сөрген бистәсендә аерым өйләр салып керергә рөхсәт иттеләр. Исән калган татарларның барысы да диярлек үз гаиләсенә алачык булса да әтмәлләп керде. Тимербулат картның ярдәме белән Асылгәрәй карт бистә уртасында агач йорт җиткереп чыкты, кысан бараклардан соң бу инде аларга җәннәт почмагы булып күренде. Һәм алар гомер буе шунда яшәделәр. Алтмышынчы елларда әтиләрен соңгы юлга да шуннан алып киттеләр.

Әмма сөргендәгеләр өчен озак еллар төрле чикләүләр яшәп килде, аларга авыр вакытта матди ярдәм дә күрсәтмәделәр, укырга да үзләре теләгән урынга керергә рөхсәт итмәделәр. Шуңа күрә югары белемне дә озак еллар, урау юллар аша алырга туры килде. Мәрзия абыстай үзе дә шулай итеп башта Троицк педагогия училищесын тәмамлады, аннан соң гына Магнитка педагогия институтында читтән торып укый алды. Һәм гомер буе мәктәптә эшләде. Хәзер исә шәһәрнең абыстае булып йөри, татар балаларына гарәп теле укыта, халыкны дингә өнди...

Сөргенгә сөрелгәннәрне укырга алырга ашыгып тормасалар да, армиягә, сугышка беренче булып аларны китереп керттеләр. Самат фин сугышында ук яраланып кайтты, калган гомерен бер кулсыз үткәрде. Солтанхәким сугышның башыннан ахырына хәтле әләкте, сөргенгә сөрелгән, ышанычсыз дип тормадылар, бу татар баласын утның иң куркыныч урыннарына илтеп тыктылар. Ул берничә тапкыр яраланды, үлемнән калды, әмма әтисенең догалары, үзенең ныклы иманы аны исән калдырды. Ул әле сугышка кадәр үк Саматның кече сеңлесе Рабигага өйләнгән иде, үзе сугыштан кайтышка улы Атлас үсеп җитте. Менә шул Атласның Рөстәм исемле олы улы, ягъни Солтанхәкимнең оныгы, шушы Магнит даласында дөньяда тиңе булмаган мәчет төзетте. Мәрзия карчык ире Сәүбән белән хәзер шуның ачылышына баралар.

Мәрзия абыстай әле дә хәтерли: Сәүбән беренче тапкыр Магниткага Сарбай исемле этен ияртеп килгән иде. Соры бүрегә охшаган бу эт Асылгәрәй карт белән елый-елый чинап очрашкан иде. Әмма Сарбай Магниткада озак түзә ал-

мады, шәһәрнең урам этләре белән берничә тапкыр канга батып сугышты да яңадан үзенең Урал тауларына китеп барды. Эт өчен дә ирек кадерле иде шул, бигрәк тә Сарбай кебек тау бүресе нәселенә…

Сәүбәнне бирегә китерү белән, Асылгәрәй карт аны һөнәр училищесына укырга бирде. Ул аннан берничә елда тимер коярга өйрәнеп чыкты, аны тәмамлагач, егетне иң җаваплы урынга — домна мичәнә куйдылар. Сәүбән шунда эшләп, кичке мәктәпне тәмамлады, аннан читтән торып металлургия институтына барып керде. Шушы тимер заводында Сәүбән гади эшчедән директор ярдәмчесенә хәтле күтәрелде, гыйлеме һәм әхлагы белән биредә аңа тиңнәр булмады. Алланың рәхмәте, эше бик җаваплы булгач, аны сугышка да алмадылар, бронь белән калдырдылар. Сугыш елларында алар Мәрзия белән яратышып өйләнештеләр, Сәүбәнгә шунда ук заводтан бер кечкенә бүлмә дә бирделәр, һәм алар үз тормышлары белән яши башладылар. Бергәләп Акбулатка да кайтып йөрделәр, исән вакытта әнисе үзе дә бирегә еш килеп йөрде, әмма бөтенләйгә авылдан китәргә теләмәде. Мәрзия абыстайның биш баласы да Акбулатны бик ярата, җәйләрен әтиләренең төп нигезенә кайтып йөриләр. Урал аръягындагы Зәйтуганга караганда аларга нигәдер Агыйдел буендагы Акбулат якын. Бәлки, Асылгәрәй бабаларының кабере шунда булгангадыр. Бәлки, башка сәбәп беләндер. Алар җыелышып Акбулатта бер дигән мәчет җиткерделәр, ел саен кайтып Коръән укыталар. Акбулат халкы үзе дә бик дини, биредә авылга аракы кертмиләр, харам тыелган, яшәү рәвеше Асылгәрәй карт өйрәтеп калдырганча дәвам итә.

Ә Зәйтуганда тормыш башкачарак инде. Анда нишләптер дин яңадан кереп китә алмады. Мулла-абыстайларын таш атып куган татар авылы мантымады. Зәйтуганда, төп нигездә, һаман авыл советы идарәсе. Дөрес, артыннан йөреп, судлашып аны кире кайтарырга була иде. Әмма авыл халкының яңа идарә салырлык мөмкинлеге юк, анда хәзер почта да, медпункт та, кыскасы, Зәйтуганның бөтен тормышы Асылгәрәй хәзрәт йортында. Шулхәтле мәҗбүриләп, кан костырып төзелгән колхозлар инде беткән, талыйсы малны җитәкчеләр талап бетергән һәм аның урынына фермер хуҗалыклары төзегәннәр. Кыскасы, Зәйтуганның бөтен байлыгы, җир-сулары яңадан Шайтан Шакир нәселе кулына күчкән. Бу якларга хәзер алар хуҗа булып калган…

Ә Шайтан Шакир үзе юкка чыккан…

Ниндидер гаебен табып, утыз җиденче елны аның үзен дә Магнитка төрмәсенә җибәрәләр. Биредә ул сөргендәге авыл-

дашлары күргән бөтен газапларны, авырлыкларны, мәсхәрәләрне үз башыннан кичерә. Холкы яман булганга, аны гел эт типкесендә йөртәләр, кыйналудан башы чыкмый. Тәмам гарипләнеп, сыңар күз белән срогын тутырып чыккач, ул Асылгәрәй картның сөрген бистәсендәге агач өен эзләп табып килгән иде. Мәрзия әле ул хәлне яхшы хәтерли. Идәнгә тезләнеп, Шайтан Шакир Асылгәрәй карттан гафу үтенгән иде. Елый-елый, башын идәнгә бәрә-бәрә кичерү сораган иде. Асылгәрәй карт шул чакта аңа:

— Син Аллаһы Тәгаләдән кичерү сора, аның алдында тәүбәгә кил, — дигән иде.

Алар Шайтан Шакирны ашатып-эчертеп, юллык акча биреп, киендереп озаттылар.

Шайтан Шакир Алла алдында тәүбәгә килгәнме-юкмы — анысы билгесез, әмма ул төрмәдән авылга кайтып җитә алмаган. Аны поездадан Урал таулары арасына атып калдырганнар. Моның сәбәбен дә белүче булмады, гәүдәсен дә эзләтмәделәр, кешечә күмүче дә булмагандыр, мөгаен. Тәкъдирендә шулай язылган булгач, ул да Урал тауларындагы кырык сыртның берсендә ерткыч җанварларга азык булып ятып калган.

Утызынчы елларда Шайтан Шакирдан качып, Равил абыйларына кияүгә чыккан Вәсимә җиңги гомерен шул Ташкент якларында яшәп бетерде. Ире сугышта хәбәрсез югалды, балалары үзбәк арасында төпләнеп калдылар, укып, зур кешеләр булдылар, югалмадылар. Вәсимә җиңги инде күптән гүр иясе, Асылгәрәй карт аның үзе белән дә, балалары белән дә беркайчан да арасын өзмәде, нәселенә дә шуны васыять итеп калдырды. Ул теге еллар өчен олы килененә үпкә-ачу сакламады, үзенең сөргенгә сөрелүен аннан күрмәде. Чөнки Вәсимә килен Шайтан Шакирны ташлап, Равилгә чыкмаса да, Асылгәрәй хәзрәтнең нәселе барыбер совет төзегән кара исемлектә булган булыр иде. Аларны барыбер авылдан сөргән булырлар иде. Шайтан Шакир шушы режимның себеркесе, әмерләрен үтәүче генә булды. Канлы әмерләр исә аңа югарыдан бирелгән иде. Алар Казаннан гына түгел, Мәскәүнең үзеннән килә иде. Әлбәттә, аны үтәмичә калырга да була иде, әмма бөтен кеше мондый батырлыкка әзер түгел шул. Шайтан Шакир кебек сәнәктән көрәк булган затсызлар — бигрәк тә. Әнә хәзер дә авылны алар сатып алган...

Сталин үлгәч, илле дүртенче елның җәендә Мәрзия әтисе һәм ире Сәүбән белән кайтып килде Зәйтуганга. Сәүбән ул вакытта Магниткада инде зур эштә иде, заводтан махсус машина алып кайттылар. Ул вакытта әле Сабира апалары исән

иде, Гарифҗан җизниләре исә сугышта үлеп калган. Туп-туры аларга кайтып төштеләр. Министрлар машинасы — кара «Волга»да кайтып төшкән Асылгәрәй картны карарга бөтен авыл җыелды. Аларның үз өйләрендә әле һаман колхоз идарәсе, авыл советы иде, шуңа күрә йөрәк бозып анда кереп тә тормадылар. Мәрзия генә, сагынуына түзә алмыйча, нигездәге ак ташларны сыйпап елаган иде. Алар утырткан алмагачлар инде күптән корыган, гөрләп гөлләр үсеп утырган ишегалды такыр җиргә әйләнгән. Мәрзия, Зәй буена төшеп, бөдрә талларны кочып, үксеп-үксеп елаган иде. Игезәк туганы Рәйсәнең сөргенгә сөреләсе көнне судан чыкмыйча йөзүен күз алдына китерде. «Бармыйм, анда су булмый», — дип елаган иде, мескен. Һәм сөрген юлында, мал вагонында суга тилмереп үлде...

Зәйтуганда әниләре рухына яшереп кенә Коръән укытып киткәннәр иде...

Ирләр зиратка барып дога кылдылар...

Шул вакытта әтисе Зәйтуган белән дә, хәләленең кабере белән дә мәңгегә хушлашкан булган икән...

Ул үзен күмәргә нигәдер Зәйтуганга кайтарырга кушмады, туксан яшендә намазлы Акбулат авылының җылы туфрагына кереп ятты. Кияве Сәүбән аны үз куллары белән юды, кәфенләде, җеназа укып, үз куллары белән туган авылына җирләде. Асылгәрәй хәзрәт Уралтау араларында, Агыйдел буенда мәңгелеккә ятып калды. Аның үзен сөргенгә сөргән Зәйтуган авылында да, таш төрмәләрендә тоткан Магнитка шәһәрендә дә туфракка иңәсе килмәде. Ул җанына тынычлыкны Урал тауларында тапты, кырык сырт арасына кайтып ятты. Бу аның соңгы теләге иде...

Дөрес, туксанынчы еллар уртасында Мәрзия абыстай ире һәм балалары белән Зәйтуганга тагы бер кайтып килде. Сабира апасының балалары иске мәчетне яңадан торгыздылар, Зәйтуганда яңадан мәчет эшли башлады. Бу Асылгәрәй хәзрәт мулла булып торган борынгы таш мәчет иде, хәзер анда аның оныгы имамлык итә. Ул вакытта да, менә шулай бөтен нәсел җыелып, әти-әниләре, кардәшләре рухына Коръән укытканнар, дога кылганнар иде. Әмма авылда халыкның мәчеткә аз йөрүенә Мәрзия абыстайның җаны бик әрнегән иде. Югыйсә дин тотарга ирек бит, беркем моның өчен сөргенгә сөрми, төрмәләргә утыртмый. Ә халык дин тотмый. Һәр йортта аракы, һәр йортта телевизор, авыл халкына хәзер шулар хуҗа. Очлытау буйларында, Алыптау өсләрендә, бакча башларында, чишмә яннарында көне-төне нефть көянтәләре эшләп тора; Зәйтуганның җир маен, йөрәк маен Мәскәү урыс-

ларына, Казанның сатлык татарларына ташып тора. Калдык-постыгы Шайтан Шакирлар нәселенә дә эләгә, алар биредә шул байлыкны каравыллап торучы. Ә Зәйтуган халкына пычрак тозлы сулар, нефть баскан дегетле елгалар, көйгән кырлар кала. Авылны кырып килгән яман шеш авыруы кала, эчкечелек, караклык, каралык кала...

Мәрзия абыстай әтисенең ни өчен үлгәч бирегә күмдермәвен аңлады...

Туган җире булса да, аның намазсыз туфракта ятасы килмәгән...

Үлгәч тә, Шайтан Шакирлар нәселе кулына каласы килмәгән...

Ул арада Асылгәрәй хәзрәт утары мәчет ачарга баручы халык белән тулды. Ишле нәсел яшәгән бу авылны халык телендә шулай дип атап йөртәләр. Магнитканың уртасында, Җаек елгасы буенда төзелгән мәчеткә дә Асылгәрәй хәзрәт исеме бирелде. Һәм анда Асылгәрәй хәзрәтнең төпчек улы Солтанхәким муллалык итә иде.

Менә алар, унлап машинага төялеп, Җаек аръягына, мәчет ачылышына баралар. Монда Равил белән Сабираның да балалары һәм оныклары бар, Гайшә белән Саматның да ишле нәселе, Солтанхәкимнекеләр дә, Мәрзия белән Сәүбәннең балалары һәм оныклары да җыелган. Биредә Зәйтуган халкы да, Акбулатныкылар да, Үзәнбаш авылыннан да татарлар килгән. Аларны мәчет янында сөргенгә сөрелгән татарларның ишле нәселе көтә. Язмышларындагы кырык сыртны җиңеп исән калган татарлар. Алар биредә утыз меңләп.

Әнә алар диңгез булып, мәчеткә генә сыймыйча, Магнитка урамнарына таралганнар...

Җир асты куышларында, бозлы баракларда яшәп, чабатадан шәһәр салган затлы татар нәселе...

Аллаһъяр хәзрәт, Асылгәрәй мулла, Әхсән хәзрәт, Мөбарәкша мулла, Габдрахман хәзрәт, Гариф мулла, Хәлил хәзрәт, Сәгыйть мулла, Госман хәзрәт, Шәмселмөхәммәт мулла һәм Магнитка сөргененә сөрелгән меңләгән татар муллаларының балалары, балаларының балалары...

Сөргенгә сөрелгәннәрнең бишенче буыны...

Аларга алтмыш ел буе илгә кайтып төпләнергә рөхсәт бирелми, алар гомер буе сөрелгән хокуксызлар исемлегендә йөриләр. Инде заманалар үзгәреп, аларның намуслы исемнәре акланганда, татарлар шушы таш-тимер арасына тамыр җибәреп өлгергән булалар. Уралтауның кыя-ташларына тотынып үскән карагайлар кебек, алар да сөрген җирендә тамыр җибәрәләр һәм яшәп калалар. Өлкән буын һаман иске

агач бистәләрдә, үз өйләрендә яшәп ята, яшь буын инде яңа шәһәргә, Җаекның бу ягына күчеп бетә.

Бистәләрдә вакытта аларның үз татар мәктәпләре, яшерен мәчетләре, милли театрлары була, әмма шәһәрнең урыс җитәкчелеге аларны әкренләп юкка чыгара. Заманалар үзгәргәч, мәчетләрне татар байлары үзләре салдыра башлый, ә менә мәктәп ачарга биредәге татарларга барыбер рөхсәт бирмиләр. Илле-алтмыш ел буе гел урысча гына укырга мәҗбүр булган сөрелгән татарларга хөкүмәт яңадан ана телләренә кайтырга ирек бирми...

Заманында Зәй, Мишә, Идел һәм Кама буйларыннан сөрелгән татарлар миллилекне өйләрендә, күңелләрендә булса да сакларга тырышалар. Аларның җырлары гел туган ил турында була. Заманалар үзгәргәч, сөрелгәннәрнең оныклары биредә җирсеп үзләренең үзешчән сәнгать түгәрәкләрен оештыралар, милли җырлар, милли киемнәр, милли ризыклар аша Җаек буенда татар тормышын торгызырга тырышалар. «Асылъяр» дип аталган милли көйләр түгәрәген теге вакыттагы гармунчы егетнең оныгы җитәкли, аның үзен дә Асылъяр дип атап йөртәләр. Бүген, мәчет ачылганнан соң, клубта халыкка милли көйләр, бәетләр һәм мөнәҗәтләр кичәсе үткәрәчәкләр, анда Мәрзия абыстайның оныклары да катнаша. «Кырык сырт» мөнәҗәтен дә бүген алар башкарачак...

Шәһәрдә һәр елны Хәтер кичәләре уздырыла...

Бу Явыз Иван Казанны алган октябрь уртасына туры килә...

Сөргенгә сөрелгән татарлар өчен урыс Иван белән коммунист Сталин икесе бер дәрәҗәдәге явызлар...

Алар тарафыннан газап күргән татарлар — бер дәрәҗәдәге шәһитләр...

Бу кичәләргә сөргенгә бала вакытта сөрелгән иң карт буын килеп утыра. Мәрзия абыстайлар буыны. Хәзер инде аларга да сиксән-туксан яшь... Солтанхәким хәзрәт сөргендә үлеп калган муллалар рухына багышлап ел саен Коръән мәҗлесләре уздыра, йөзләгән исемлекне укып чыгу гына да сәгатьләр буе бара. Ачтан үлгән, кыйналып үлгән, каты газаплардан сөргендә дөнья куйган татар муллалары... Иң авыр вакытларда да диннәрен ташламаган, Аллаһтан өметләрен өзмәгән, балаларына да шуны васыять итеп әйтеп калдырган татар муллалары... Урыныгыз җәннәттә булсын сезнең...

Җаек буйларын тетрәндереп манарадан азан тавышы яңгырый...

Азанны Мәрзия абыстайның Мәккәдә укучы оныгы әйтә...

Утыз мең татар кыйблага карап, җиргә тезләнеп намаз укый...

Аларны алтмыш ел буе тоткын итеп тоткан корымлы таш шәһәр йөзләгән кара торбасы белән, меңләгән урыс-марҗасы белән коты чыгып аларга карап тора. Чөнки бу татарлар бирегә иман өчен түгел, тимер өчен куып китерелгән иделәр. Алар көне-төне тау актарып, мәгъдән чыгарырга, утлы мичләр каршында чуен коярга, дала җилендә йортлар салырга тиешләр иде. Татарлар монда үлгәнче эшләү өчен кол итеп куып китерелгән иде. Ә алар әнә күккә карап азан әйтәләр, җиргә тезләнеп намаз укыйлар, дөньяда тиңе булмаган мәчетләр салалар, Коръән өйрәнәләр, һаман үз телләрендә сөйләшергә тырышалар, үз җырларын җырлыйлар, үз милли ризыкларын ашыйлар, үзара өйләнешәләр, үз тарихларын беләләр, аны кадерләп саклыйлар, буш далада да мөселман-татар булып калу өчен көрәшәләр... Алар Җаек далаларында да татар, Урал тауларында да татар, бөтен дөньяда татар булып яшиләр...

Ә шәһәргә барыбер татарлар түгел, сөрген коменданты Шишкаловлар һәм Коноваловлар нәселе хуҗа. Миллиард долларлар керем бирүче металлургия комбинатына төрмә начальнигы Гейнманнар нәселе хуҗа. Һәм алар бу байлыкны беркем белән дә бүлешергә җыенмыйлар. Шул исәптән шушы байлыкны тудырган татарлар белән дә.

Югыйсә Россия әсирлектә булган кешеләре өчен Германиядән зур суммада акчалар түләтә, яһүдиләр дә, немецларның бугазларына басып, үткәндәге газаплары өчен әҗерен алып яталар. Ә Россия сөргеннәрендә газап күргән татарларга кем әҗерен түләр? Магнитка төзелешендә генә дә, адәм түзә алмаслык сөрген шартларында, һәр гаиләдән өчәр-дүртәр татар кешесе үлде, алар өчен кем җавап бирер? Татарлар Россиягә үз сөякләре өстендә металлургия комбинаты һәм шәһәр төзеп бирделәр, ә аларга биредә үз ана телләрендә мәктәп ачарга да рөхсәт юк. Югыйсә комбинаттан килгән миллиард долларларга һәр татарга алтыннан йорт салып бирергә булыр иде, татарча мәктәпләр генә түгел, югары уку йортлары ачарга булыр иде. Биредә мәчетне дә халык үз акчасына салды, ә Җаек буендагы яңа чиркәү өчен шәһәрнең урыс җитәкчелеге йөз миллион сумга якын акча бүлеп бирде. Биредә татарларның үзләрен, исемнәрен, тарихларын оныттырыр өчен барысы да эшләнә. Татарлар да моны яхшы белә, үзләрен төрмәдә тоткан бу илдән мәрхәмәт көтми, алар бары тик үз көчләренә генә таянып яшәргә мәҗбүрләр...

Шуңа күрә әнә алар Җаекның ике ягыннан, тарихның ике ярыннан бер-берләренә карап торалар…

Бер якта — күккә тигән мәчет манарасы, икенче якта — күкне кара төтен белән каплаган завод торбалары…

Бер якта — иманлы, затлы, тырыш татар халкы, икенче якта — дала-тауларны талау өчен килгән кяфер кавем…

Ике арада — мәңгелектән агып килгән Җаек елгасы һәм кыйтгаларны аерып торган Урал таулары…

Һәм һәркем өчен язмышында билгеләп куелган кырык сырт…

Һәм татар муллалары артыннан шушы кырык сыртны исән-имин чыгып килүче татар халкы…

Милләт бу тарихи чорны исән-имин үтеп өлгерсен иде, чөнки илгә тагы чекист Кандыбиннар заманы килә…

Россиядә яңадан сөрген һәм төрмәләр чоры килә.

Һәм бу чорны, язмышындагы кырык сыртны, иманы нык-лар гына исән-имин үтә алачак…

Һәй… Һәй… Һәй…
Урал тауларында кырык сырт…
Урал тауларына үпкәләмим,
Язмышкайларымда кырык сырт…

Һәй… Һәй… Һәй…
Урал тауларында кырык сырт…
Язмышкайларыма үпкәләмим,
Милләт тарихында кырык сырт…
Һәй… Һәй… Һәй…

*30 март, 2005*



# КАРАБОЛАК

## БЕРЕНЧЕ КИТАП

### **Беренче бүлек**

1946 елның җәе коры килде...

Май аеннан кара көзгә хәтле бер тамчы яңгыр төшмәде, көздән чәчкән игеннәр тамырдан корыды, яз чәчкәннәре бөтенләй тишелеп чыкмады. Бар өмете бәрәңгедә булган авыл халкы, җәй буе яңгыр яумагач, бәрәңгесез дә калганын аңлады. Кемдер һаман күккә карап яңгыр көтте, бакчасына көянтәләп су сибеп, бәрәңгесен коткарып калырга тырышты, әмма җәй уртасына ул җирләр кара көйгән, бәрәңге сабаклары корыган иде инде. Яңа гына авыр сугыштан котылган, ярты авыл ятим һәм гариплардән торган Караболак халкын шом басты, кем ничек булдыра, шулай озын һәм салкын кышка әзерләнә башлады...

«Бөтен ил белән шушы хәл» дисәләр дә, Урал аръягына урнашкан Татар Караболагы авылы халкына, бу тирәдә яшәүчеләргә бу корылык икеләтә газап алып килде. Беренчедән, үз гаиләләре өчен каты курку булса, икенчедән, бу як халкы, үз авызларыннан өзеп, Иртәштә төзелеп яткан Базаны ашатырга тиеш иде. Кем ул База дигәннәре, нәрсә — анысын Караболак халкы белеп тә бетерми, әмма кара урман эчендә барган ул төзелешне ашату алар өстенә йөкләтелгән. Һәр йорт башына мәҗбүри төшерелгән салым бар, каян алып, ничек түләргә тиеш аны авыл халкы — ул турыда алардан сораучы юк. Имеш, Иртәш күле буенда Чиләбе кебек зур шәһәр төзелә икән, Караболак халкы да шунда барып, рәхәтләнеп яши, эшли алачак, ди. Имеш, яшьләргә хәтта армия хезмәтен дә шунда гына үтәргә мөмкин булачак икән. Бу төзелешләр Караболактан 30—40 чакрымнарда гына булганга, авыл халкы моны башта сөенеп кабул итте. Әмма Иртәш төзүчеләрен үз авызларыннан өзеп ашатырга кирәклеген белгәч, аларның шатлыклары тиз юкка чыкты. Алар өчен бүгенге көндә үз тормышларын алып бару, үз гомерләрен саклап калу мөһимрәк иде. Көтүдән ач кайткан бу сыерлардан ничек итеп сөт аласың да, үзеңнең ач балаларыңа бирмичә, ул сөтне ничек итеп Иртәшкә озатасың инде? Тавык ар-

тыннан төшкән һәр йомыркаΝы алтын күкәй кебек кадерләп җыеп барган хатын-кызлардан аны ничек тартып аласың да, Иртәш төзүчеләренә бирәсең? Кыш ашатырга азыклары булмаган арык сарык малын үзең суеп ашыйсыңмы, тагы шул күзгә күренмәгән Базага җибәрәсеңме?

Авыл советы рәисе Нәбиулланың башында хәзер әнә шул уйлар гына... Район үзәге Коншактан ул борчулы уйлар белән кайтып килә. Аларга анда бик каты әйтеп җибәрделәр — бу мәсьәләдә бернинди саботаж, сүз тыңламау булырга мөмкин түгел, һәр авыл үзенә бирелгән бурычны үтәргә тиеш икән. Татар Караболагының элек-электән баш бирмәс мишәр авылы булганлыгын белгәнлектән, Нәбиулланы кат-кат кисәттеләр, ил, дәүләт, партия исемнәре белән куркыттылар, Сталин, Берия исемнәре белән янадылар. Җыелып килгән авыл җитәкчеләренә Иртәштәге төзелешнең гаять мөһимлеген кат-кат исләренә төшерделәр, аны өзүче халык дошманы дип аталачагын әйттеләр. Әмма нәрсә төзиләр Иртәштә шулай ашыга-ашыга, нигә ул шул дәрәҗәдә серле һәм хәвефле — ул турыда берни әйтмәделәр, бу турыда артык төпченмәскә куштылар...

Әмма Нәбиулла — сигез ел армиядә булып кайткан кеше, шуның биш елы сугыш кырларында үтте. Ул җилнең кайсы якка искәненә карап та тиешле нәтиҗә чыгарырга өйрәнде инде, тормыш өйрәтте. Биредә дә ул тиз чамалап алды — артык сүз куертмыйлар икән, димәк, бу төзелештә ниндидер хәрби сер бар. Аларның анда Чиләбе кебек шәһәр төзеп ятуларына Караболак хатыннары гына ышаныр ышанса. Кара урман уртасында, күлләр белән чорналып алган сазлыклы урынга нигә дип шәһәр китереп төзесеннәр икән? Аның өчен әнә шул ук Чиләбе өлкәсендә дә буш яткан күпме кыр-дала бар, кил дә шәһәр төзе шунда. Юк, боларга нәкъ менә Уралтау итәгендә булган шушы кара урманнар, диңгезләргә тиң саф сулы күлләр, Караболак, Кояш, Мусакай авыллары тирәсендәге җәннәттәй җирләр кирәк булган. Моның сере, хикмәте нәрсәдә икән? Нәрсә төзиләр алар анда, бөтен дөньялары белән кубарылып?

Коншакта бер хәбәр ишетте ишетүен Нәбиулла — имеш, атом сугышы була калган очракта, хөкүмәтне Мәскәүдән шушында күчерәселәре икән, шулар өчен җир асты шәһәре төзиләр икән Иртәштә. Бу чыш-пыш инде халык арасында шактый таралып өлгергән, аны тыючы да, артык куертучы да юк. Әмма Нәбиулла бу хәбәргә артык ышанып бетмәде. Айһай, әллә кайдагы Урал артына күчерерләрме икән хөкүмәтне Мәскәү хәтле Мәскәүдән? Күчерсәләр дә, әнә шул Куйбышев тирәләренә күчерерләр... Ә менә атом сугышы ди-

гәннәренә колаклары торды Нәбиулланың. Кем белән атом сугышы? Кара-каршы сугышу өчен, тагы кемдәдер атом бомбасы булу кирәк бит. СССРда хәзергә ул юк, булса, бөтен дөнья белер иде... Бүгенге көндә бары тик Американың гына атом бомбасы барлыгы билгеле, ул аны узган ел Япония өстенә ташлады. СССР газеталары бу хакта күп яздылар, әле кичә генә Германиягә каршы сугышта союзниклар булган Американы пыр туздырып, гаепләп ташладылар, халыкны яңа атом сугышы белән куркыта башладылар.

Нәбиулла шулай уйларга өлгермәде, бөтен дөньяны кот чыгарлык көчле шартлау тавышы тетрәтте, аяк астында җир сикереп куйган кебек булды. Иртәш борылышына җитеп килгән туры айгыр бу көтелмәгән тавыштан башта чүгеп, туктап калды, аннан, кая барганын белмичә, күзе-башы тонып, котырып чаба башлады. Нәбиулла дилбегәне уң кулына чорнап тотты, очып барып төшмәс өчен, гарип сул терсәге белән арба төбенә таянды. Ул арада Иртәш ягында тагы көчле гөрселдәү тавышы ишетелде, бу тавыштан хәтта юл читендәге агачлардан соңгы яфракларга хәтле коелып төште. Шартлау турында уйлаганчы, Нәбиуллага башта туры айгырны тыярга кирәк иде, чөнки ул, Караболак борылышын узып китеп, туп-туры Сверлау ягына карап чаба башлады...

Ат үзенең чабышын бераз акрынайткан арада, Нәбиулла арбадан сикереп төшеп, туры айгырның башына барып ябышты. Айгыр, авыз тирәсендә ак күбекләрен пошкыртып, күзләрен алартып, хуҗасына карап торды да, аның кул көченә буйсынып, артка таба чигенә башлады. Нәбиулла аны шулай чигендерә-чигендерә кирегә борды һәм Караболак юлына чыгарды. Шартлау яңадан кабатланмады, ат тынычланды, алар сикәлтәле юл буйлап авылга таба юнәлделәр. Бераз тынычлангач кына Нәбиулла теге серле шартлау турында уйлый башлады. Гадәттә, вак-төяк төзелеш эшләрендә мондый хәрби шартлатуларны кулланмыйлар, мондый шартлатулар таш кирмәннәрне җимергәндә яки бик тирән баз-котлованнарны казыганда гына кулланыла. Димәк, Иртәштә, чыннан да, дөньяда тиңе булмаган зур төзелеш бара, димәк, бу эшкә хәрбиләр дә тартылган һәм ул хәрбиләр өчен кирәк булырга тиеш. Һәм, халык сөйләгәнчә, җир асты бункерлары төзегәнгә охшаганнар, тик нәрсә өчен, кемнәр өчен ул җир асты төзелешләре? Нигә аның тирәсендә шулхәтле сер, әйтеп бетермәү, нидер яшерү, янау һәм куркыту соң? Авылдагыларның да котын алгандыр бу шартлаулар, өйдәгеләр аның өчен хафага төшмәсеннәр тагы.

Өйдәгеләр турында уйлауга, Нәбиулланың күз алдына хатыны Хәбирә килеп басты. Ул бүген-иртәгә бәби табарга

тиеш, насыйп булса, Нәбиулла кулларына алачак беренче баласы. Кулларына алачак, ди, чөнки аның беренче баласы ул 1937 елда солдат хезмәтенә киткәч туа һәм, әтисен бер тапкыр да күрмәгән килеш, якты дөньядан китеп бара. Сигез елга сузылган армия, сугыш, яраланулар, больницалар аның яшьлеген дә, гаилә тормышын да, беренче баласын да урлады. Менә хәзер ул, утыз яшенә җитеп килгәндә, тагы беренче баласын көтә. Кем генә булса да — малаймы, кызмы — ул Нәбиулла өчен дөньяда иң газиз кеше булачак, яшәү мәгънәсе, җан тынычлыгы булачак. Сугыш кырларында, ак кар өстендә яралы хәлдә үлем көтеп ятканда, ул Аллаһтан бер генә нәрсә сорады — нәсел, балалар калдырырлык гомер. Нәбиулланың нәселсез, баласыз килеш бу якты дөньядан китәсе килми иде. Чөнки аларның Караболак авылында бары тик зур нәселле, ишле балалы йортны тота алган кеше генә чын ир-ат санала. Бар балаларын да тиешенчә урнаштырган, белем һәм һөнәр биргән, башлы-күзле иткән ата гына ил агасы була ала. Алар авылында Нәбиуллага хәтле дә шулай булган, йөз ел элек тә шулай яшәгәннәр, хәзер дә, шөкер, нәкъ шулай дәвам итә. Авыл халкы яхшы нәселгә, яхшы ата-анага, акыллы, таза-сау балаларга зур игътибар бирә. Шушындый сугышлардан да исән калган, ут, үлем эченнән исән чыккан Караболак егете Нәбиулла кемнән ким? Ул сугышта үзенә сүз бирде — исән кайтсам, бер дистә балабыз булыр, диде. Инде менә Хәбирәсе аңа шушы бәхетне бирергә тора — бүген-иртәгә бәби көтә алар. Нәбиулла да утыз яшендә кулына беренче баласын алачак, Алла теләсә!

Шушыларны уйлагач, аңа туры айгыр акрын бара кебек тоелып китте. Ул баш очында дилбегәсен уйнатып, атның янбашына тартып җибәрде. Туры айгыр, тагы күзләрен алартып, кушаяклап чабып китте. Аның үзенең дә бу ерак юлдан тизрәк авылга кайтып җитәсе, туйганчы Караболакның йомшак суын эчәсе, туйганчы солы чемченәсе килә иде... Караболакка алар кичке якта, көтү кайткан турда кайтып керделәр. Акрын гына атлаган арык малларны аралый-аралый, өй турларына кайтып җиткәндә, Нәбиулланың йөрәге күкрәгеннән чыгарлык булып ашкынып тибә, күңеле, уйлары үзеннән дә алда оча иде...

Нәбиулланың ашкынуы, өмет-хыяллары юкка гына булмаган икән — ак пәрдәләр тарттырылган ачык тәрәзәдән бөтен урамга, юк, бөтен дөньяга бала елаган тавыш яңгырый иде! Юк, мескен, шыңшып елау түгел иде бу, ә бөтен җиһанны тетрәтеп, дөньяга килү турында хәбәр бирү, ярсып аваз салу иде! Бу тавыштан Нәбиулланың тез буыннары йомшарып китте, күзләренә яшь бәреп чыкты. Үз баласының шу-

шы беренче авазы аңа дөньяда иң матур, иң көчле, иң моңлы тавыш булып ишетелде. Сугыш кырларында, җир асты кушыларында, яуга күтәрелгәндә, яраланып, берьялгызы үлем көтеп ятканда, больницаларда аның колагына ничә тапкыр менә шушы тавыш ишетелгән иде инде! Үз баласының беренче авазы, Алып Хан нәселенең ораны менә нәкъ шундый булып ишетелгән иде аңа.

Ул атылып өйгә керде. Өйдә кайнашкан хатын-кызларны бөтенләй күрмичә, ул бала тавышы ишетелгән якка — чәчәкле чаршауга таба атлады. Калтыранган куллары белән чеметеп кенә чаршау читен ачты, иң беренче килене янында кайнашкан әнисен күрде, аннан карашы илаһи бер күренешкә тап булды. Чәчәкле ястык-түшәк өстендә, ак биләүгә төргән сабыйны кочагына алып, Хәбирәсе елмаеп ята иде.

— Менә, әтисе, сиңа кыз алып кайттым, — диде ул, нигәдер бераз уңайсызланган кебек.

— Кыз?! — диде Нәбиулла, чын-чынлап гаҗәпләнеп. — Тавышы буенча, мин аны малайдыр дигән идем. Урамның теге башына ишетелә бит тавышы!

— Аллага шөкер, дүрт саны исән, таза-сау бала, — диде шунда Нәбиулланың әнисе Нурҗамал карчык та, сүзгә кушылып. — Бәхете белән тусын, нәселебезне дәвам итсен...

Карчык шулай гөрли-гөрли чыгып китте, Нәбиулла исә тизрәк хатыны янына килеп тезләнде. Аның бу кечкенә ак йомгакны җентекләп карыйсы, кулларына аласы, күкрәгенә кысасы килә иде. Чөнки озак, бик озак көтте Нәбиулла аның дөньяга килүен.

— Сиңа охшаган, — диде Хәбирә, йокылы-уяулы яткан кызчыгын иренә таба борып.

Нәбиулла күзләре белән генә түгел, бөтен йөрәге, җаны-тәне белән баласына капланды. Чынлап та, бала нәкъ Нәбиулла кебек иде! Ул биләүгә сыярга теләмичә киерелеп яткан эре гәүдә, нык утыртылган баш, алар нәселенең тамгасы булган төз, туры борын. Озынча алсу йөз, сызылып киткән кыйгач кашлар, бөгелеп килгән озын керфекләр. Бөтенесе үз урынында, бөтенесе шундый камил һәм матур, аңа карап соклануыннан Нәбиулла хәтта тын ала алмыйча торды. Охшаса да охшар икән бала шулхәтле Алып Ханнар нәселенә! Нәкъ шундый бала туар дип көткән, өмет иткән иде бит Нәбиулла. Хәбирәсе аңа нәкъ ул теләгән баланы бүләк итте, нәсел дәвамчысын тудырды, рәхмәт яугыры!

Ул, хисләнеп китеп, хатынының кайнар кулларыннан кысты. Хатыныннан сөт исе, бәхет исе килә иде.

— Исемен ничек куярбыз соң, әтисе? — диде Хәбирә, бераз иркәләнә төшеп.

— Исеме? — Нәбиулла бераз уйланып утырды. — Исе-

ме Гөлҗиһан булыр, әнисе. Авылның гына түгел, бөтен җиһанның гөл-чәчкәсе булырлык бала бит ул, әйеме, кызым?

Гөрләп торган бу тавышка бала томырылып зур күзләрен ачты. Ата белән баланың карашлары бер мизгелгә очраштылар, таныштылар һәм бер-берләрен мәңгегә табыштылар. Нәбиулла шуны сизеп өлгерде — яңа туган сабыйның карашында ниндидер җитдилек, олы мәгънә бар иде. Ул әтисенә дә, бу якты дөньяга да сынап, олыларча карап ята. Аннан бала башын әнисе ягына борды, сөт исен эзләп, борынын аның күкрәгенә төртте. Әнисе ярдәме белән үзенә кирәкне эзләп тапкач, ул комсызланып имә башлады. Аңа хәзер ашарга, яшәргә, үсәргә кирәк иде. Аңа Караболакта Алып Ханнар нәселе дип аталып йөрткән токымны дәвам итәргә кирәк. Әби-бабалы, ата-аналы, зур нәсел-нәсәпле абруйлы татар гаиләсендә туган Гөлҗиһан исемле кыз бала бөтен нәсел өчен, авыл өчен, милләт өчен көрәшче булып үсеп җитәргә тиеш... Бу юлда аны зур сынаулар, зур газаплар, зур югалтулар һәм зур саваплар көтә иде. Әмма хәзергә ул үзе әле бу хакта белми, әти-әнисе янында, фәрештәләр саклавында Гөлҗиһан дөньяга беренче авазларын сала иде...

## Икенче бүлек

1946 елның сентябрь башында, Караболак авылында Гөлҗиһан исемле кыз бала дөньяга килгән көннәрдә, Иртәш күле буенда беренче совет атом бомбасына нигез салдылар. Биредә «Аннушка» дип аталган беренче атом реакторы өчен баз казый башладылар, анда атом бомбасы өчен ураннан плутоний аерып алырга тиешләр иде. Бу баз-котлованның тирәнлеге илле дүрт метр булып, аның аждаһа авызы йөз метрдан артык булырга тиеш иде. Бераз казуга кыя-ташларга очрауга, аларны җимерү өчен хәрби төзүчеләр иң көчле шартлаткычларны кулланырга мәҗбүр булалар. Гөлҗиһан туган көннәрдә Караболак, Иртәш буйларын әнә шул шартлаулар тетрәтә. Әмма моны хәзергә авыл халкы да, Нәбиулла белән Хәбирә дә, аларның яңа дөньяга килгән кызлары да белми әле. Хәтта баштарак төзүчеләр үзләре дә бу җир асты шәһәрен ни өчен төзегәннәрен белмиләр иде. Бу хакта Сталин, Берия, Курчатов кебек санаулы кешеләр генә белә һәм Караболак янындагы яшерен атом төзелеше белән турыдан-туры алар Мәскәүдән идарә итәләр иде...

Атом буенча беренче фәнни хезмәтләр СССРда инде 1932—1935 елларда ук күренә башлый. Әмма Германиядә, Америкада һәм Англиядә инде бу өлкәдә шактый зур ачышлар ясап өлгерәләр һәм бу хәл Советлар Союзына тынгы-

лык бирми. Бөек Ватан сугышы башланыр алдыннан Германия инде атомны таркатып, аннан плутоний ясарга өйрәнеп җитә һәм бу хакта бөтен дөньяга хәбәр бирә. 1941 елның көзендә Америка һәм Англия дә ашыгыч рәвештә атом бомбасы ясау өстендә эшли башлыйлар.

Бу шомлы хәбәрләрне берәмтекләп җыеп барган Лаврентий Берия әле 1940 елның башында ук атом коралы мәсьәләсендә Сталинга мөрәҗәгать итә, аның алдына чит илләр буенча мәгълүматны сала. Әмма фин сугышына кереп баткан Сталинга атом түгел, танклар кирәк була. Ул Бериягә шулай дип җавап бирә дә. Тик Мәскәү һәм Ленинград галимнәре инде уран, плутоний буенча эзләнүләрен туктатмыйлар, Берия дә атом бомбасы турында шымчылыгын дәвам итә. Шуның нәтиҗәсендә СССР Фәннәр Академиясенең Президиумы 1940 елның 30 июлендә уран мәсьәләсе буенча махсус комиссия төзи. 1940 елда профессор Курчатов кул астында уранның төшен таркату буенча зур ачыш ясала, бу инде атом бомбасын ясау буенча беренче адым була. Бу ачышның идеясе чит ил галимнәреннән урланган булуы турында да хәбәрләр бар, чөнки СССРга, ничек кенә булса да, бөтен дөньяны куркытып кулда тотарлык көчле атом коралы кирәк була. Шул ук елның октябрендә академик Фресман кул астындагы комиссия илдә уран ятмаларын эзләү буенча эш башлап җибәрә.

Әйткәнебезчә, Берия шымчылары чит илләрдә атомга кагылган мәсьәләләр буенча зур эзләнүләр алып баралар, чөнки фәнни-техник шпионаж да НКВД карамагында була. Шулай итеп, СССР тарафыннан Германия, Америка, Англия галимнәренең атом өлкәсендәге ачышларын урлау чоры башлана. Һәм 1942 елның башында бу мәгълүматлар тагы бер тапкыр тупланып, Берия тарафыннан Сталин өстәленә салына. Сталин атом бомбасы белән ныклап кызыксына башлый һәм галимнәр алдына тиз арада бу коточкыч үлем коралын җитештерү бурычын куя. Шул елның көзендә булачак «атом атасы» Игорь Васильевич Курчатов Казандагы эвакуация куышыннан Мәскәүгә чакыртыла. 1943 елның 15 февралендә СССР Оборона комитеты карары белән атом-төш коралы ясау буенча фәнни үзәк төзелә, аның башына академик Курчатов куела. Бу эшләрнең барысы белән дә НКВД җитәкчелек итә, СССРда атом бомбасы ясау турыдан-туры Берия кул астында бара.

1945 елның 15 июлендә Америка Кушма Штатлары беренче атом бомбасын сыный. СССР, бигрәк тә Сталин, бу хәбәрне авыр кабул итә, имеш, нигә Америка, нигә СССР түгел?! Имеш, шушылай итеп, Америка СССРдан Ватан сугышындагы җиңүен урларга тырыша. Ул арада Америка 1945

елның 6 һәм 9 августларында Японияңең Хиросима һәм Нагасаки шәһәрләре өстенә атом бомбалары ташлый. Моңа кадәр беркем белмәгән атом утында 75 мең япон бер мизгелдә тереләй янып үлә. Бу хәбәр дөньяны тетрәтә. Шулай итеп, дөнья өр-яңа чорга — атом-төш коралы җитештерү чорына керә. Илләр һәм милләтләр, бер-берләрен уздырып, коточкыч үлем коралы әзерли башлыйлар.

Әмма зур сугышлар өчен әзерләнгән бу бомбалар иң беренче чиратта шул җирдә яшәүче халыкның үз башына кара кайгы булып төшә. Атом коралы белән бергә Җир шарына моңа кадәр күрелмәгән яңа афәт — радиация тарала башлый. Шулай итеп, үлем гыйфрите шешәдән чыгарыла, атомга ияреп, күзгә күренмәс радиация килә, радиация исә яман шеш афәтен тудыра. Әмма ил җитәкчеләре атом коралы хакына бернәрсә белән дә исәпләшеп тормыйлар. Советлар Союзы да, бөтен барлыгы белән, атом-төш коралы җитештерүгә кереп бата. Сугыштан соңгы авыр бер чорда халык кулына ипи урынына атом бомбасы тоттырыла.

Дөресен әйтергә кирәк, СССРга атом бомбасын ясап бирүдә немец галимнәре, яһүдиләр зур өлеш кертә. Беренче чорда илнең хәтта үз ураны да булмый, аны җиңелгән Германиядән һәм басып алынган Чехославакиядән ташыйлар. Немец һәм яһүдиләр ярдәмендә лаборатория юлы беләнураннан плутоний эшләп чыгарырга өйрәнгәч, атом бомбасын күпләп җитештерү, ягъни куәтле атом промышленносте булдыру көн тәртибенә килеп баса. Ил сугыш хәрабәләре арасында ята, ирләр аз, халык ач, ә шулар белән атом-төш коралы җитештерергә кирәк. Сүз атом шәһәре, дистәләгән куәтле атом реакторлары, радиохимия, механика буенча йөзәрләгән җир асты һәм җир өсте заводлары, атом калдыкларын саклау объектлары төзү турында бара. Сүз тиз арада СССРның беренче атом бомбасын ясау һәм аны сынау турында бара. Һәм шушы үлем индустриясен урнаштыру буенча ил буйлап урын эзләп йөри башлыйлар.

Берия командасының Сталинны ышандыруларынча, атом бомбасы ясый торган урын үзәктән, ягъни Мәскәүдән ерак урнашырга тиеш була. Ягъни заводта атом-төш шартлавы булган очракта, хөкүмәт зарар күрергә тиеш булмый. Бериянең исбатлавынча, ул яшерен бер караңгырак почмакта булырга тиеш, ягъни чит ил шымчылары аны эзләп таба алмаслык булсын. Галимнәрнең тәкъдиме буенча, атом коралы ясый торган урын суга бик бай булырга тиеш, чөнки реакторларны бертуктаусыз суытып тору өчен бик күп күләмдә су кирәк булачак икән. Мондый көчле промышленность урнашкан җирдә очсызлы эшче көчләр, ягъни авыл халкы күп яшәргә тиеш була. Аларның бер өлеше атом объектла-

рында эшләргә тиеш булса, икенче өлеше авылларда алар өчен ризык җитештерергә тиеш. Соңгы нәтиҗә исә — СССР кулындагы көчле атом коралы, ул моның белән бөтен дөньяны басып ала һәм буйсындыра ала. Атом промышленностеның радиация белән бәйле буласын галимнәр белә, әмма бу хакта халык белмәскә тиеш була. Әле башланып та китмәгән бу төзелеш, Берия командасы ярдәме белән, коточкыч дәүләт серенә әйләнә, бу тирәдә яшәүчеләрнең туулары гына түгел, үлемнәре дә дәүләт сере төренә кертелергә тиеш була.

Шушыларның барысын да истә тотып, атом бомбасы ясау өчен Урал аръягындагы татар җирләре сайлап алына. Кара урман эчләрендәге Иртәш күле буенда, Кыштым һәм Кәсле шәһәрләре арасына СССРда беренче атом шәһәре төзергә карар итәләр. Бу урын бөтен яктан да шымчы Берия һәм атомчы-галим Курчатов планнарына туры килә. Ул Мәскәүдән ерак, аны чит ил шымчылары эзләп таба торган түгел — Урал аръягындагы кара урманнар эчендә урнашкан. Су дисәң, бөтен тирә-якта диңгез кебек дистәләгән күлләр — Иртәш, Кызылташ, Карачай, Олыагач... Очсызлы эшче көчләр дисәң — янәшәдә генә зур-зур татар авыллары, алар арасында дүртәр-бишәр мең кеше яшәгән Мөслим, Усть-Багаряк, Татар Караболагы, Коншак, Аргаяш кебекләре дә бар... Курчатов үзе дә Уралда туып үскән кеше, ул татарларның ни дәрәҗәдә эшчән, тәртипле халык икәнлекләрен белә, алар белән атом шәһәрләре төзеп буласына ышана. Хәзер шуны хәрбиләргә ышандырырга кирәк була.

1945 елның октябрь аенда урыс генераллары Завенягин һәм Комаровский, шактый түбәннән очып, «Дуглас» самолетында бу җирләрне күктән карап йөриләр. Һәм шушы мизгелдә аста үз тормышлары белән яшәп яткан татар авылларының, Уралтаудагы татар халкының язмышы хәл ителә. Атом бомбасы нәкъ менә шушында ясалачак. Һәм Сталинның махсус боерыгы белән, Иртәш күле буйларында дөньяда тиңе булмаган зур төзелеш башланып китә. 1945 елның тугызынчы ноябрендә бирегә беренче төзүчеләр китерелә, аларны брезент палаткаларга, җир куышларына, якын-тирә авыллардагы мал абзарларына урнаштыралар. Шулай итеп, хәерче ил атомга барып тотына, үз халкының бугазына басып, ул аннан атом бомбасы ясатты. Бу яшерен төзелеш, беренче көннәреннән башлап, Сталинның шәхси күзәтүендә була, аның шымчылары исә моннан кайтып кермиләр. 1946 елның җәендә һәм көзендә бирегә СССР Министрлар Советы рәисе урынбасары Л.Каганович һәм НКВД җитәкчесе Л.Берия килеп җитәләр. Һәм 1946 елның көзендә Иртәштә беренче атом реакторына нигез салалар, кыя-ташлы җирләр

болай гына бирешергә теләмәгәч, аларны теткәләү өчен хәрби шартлатулар кулланалар.

Сентябрь башында Коншактан кайтып килүче Нәбиулла Иртәш күле буеннан әнә шул шартлауларны ишетә.

Аның беренче баласы Гөлҗиһан әнә шул шартлаулар астында дөньяга килә.

Уралтау артындагы борынгы татар җирләренә атом аждаһасы чыга.

Ул җәннәт кебек татар җирләрен, кыя-таш кебек татар ирләрен тетрәтә, теткәли башлый.

Борынгы татар иленә зур афәт якынлаша...

## Өченче бүлек

Ул кышны Караболак халкы чын мәгънәсендә ачлыктан интекте. Икмәксез, мал азыгыннан мәхрүм калган кешеләрдән ит, сөт, май, йомырка планы сорап теңкәләренә тиделәр, карап торган соңгы сарыкларын алып чыгып киттеләр. Моны күреп, халык мал-туарын яшерә башлады, андыйларны исә берәм-берәм район үзәгенә чакыртырга тотындылар. Ул арада, бөтен халыкның котын алып, Караболак буенча корал тоткан хәрбиләр йөри башлады, алар инде мал-туарның гына түгел, кешеләрнең дә баш санын алалар, әллә нинди кәгазьләргә кул куйдырталар, кисәтәләр иде. Моңа кадәр батырлык, кыюлыклары белән аерылып торган Караболак халкы да курка калды, чөнки таләпләр, гомер булмаганча, бик каты иде. Иртәш, Сөнкүл, Кояш тирәсендәге урманнарга керергә ярамый, ул яктагы күлләрдән балык тотарга ярамый, бу тирәдән үрдәк-куян атарга рөхсәт юк, анда хәтта җиләк-гөмбә җыю да тыелган. Мондый хәлләрне хәтта сугыш вакытында да күрмәгән караболаклылар, хәрбиләрдән рәтле җавап ала алмагач, Нәбиулла өстенә ябырылдылар. Әмма Нәбиулла үзе дә «ярамый»дан артыгын белми кебек иде, белгән очракта да, ул аны халыкка әйтергә тиеш түгел иде.

Нәбиулла Коншактан, әлбәттә, күбрәк белеп, ишетеп кайткалый һәм бу хәбәрләрдән чәчләре үрә торырлык була Нәбиулланың. Иртәш тирәсендәге ул төзелешкә Мәскәүдән зур кешеләр — Каганович һәм Берия үзләре килеп киткәнлеге билгеле булды. Коншактан тагы шуны белеп кайтты Нәбиулла — бу тирәләрне «особорежимная зона» дип игълан иткәннәр икән. Бу зонага Кыштым шәһәре һәм Коншак, Кәсли, Аргаяш, Кузнецкий районнарының 99 авылы кергән, Татар Караболагы да шулар арасында булып чыкты. Саналган авылларның җитәкчеләрен район үзәкләренә җыеп, менә шуларны бик яхшылап аңлаттылар. Ягъни бу тирәләрдә ур-

маннарга керергә ярамый, күлләргә якын килергә рөхсәт ителми, Кыштым — Кәсли юлы халык өчен ябыла. Әмма тыюкисәтүләр әле моның белән генә бетмәгән, аның тагы да авырлары әле алда булган икән...

Нәбиулла, авыл советы рәисе буларак, Коншактан тагы яңа күрсәтмә алып кайтты — моннан соң Караболакның һәр кешесе махсус теркәлү үтәргә тиеш иде. Ягъни 1947 елның ахырына Татар Караболагы авылының һәр кешесенә паспорт бирергә һәм пропискага кертергә кирәк булачак. Ягъни авыл халкы катгый рәвештә теркәлергә һәм хисапта торырга тиеш иде. Шуннан башка авылда яшәргә рөхсәт ителми. Гомер булмаган хәл — авылда хәтта төн кунып чыгарга да һичкемне кертергә рөхсәт ителми, килгән кешегә теркәлмичә вакытлыча яшәү турында инде сүз дә була алмый. Гомер буе балалары Чиләбедә, Урал заводларында эшләп көн күргән Караболак халкы монысына бөтенләй күтәрелеп бәрелде — кунакка куна кайткан үз балаларын кая куйсыннар алар, кайда теркәтеп йөрсеннәр? Әмма Иртәш якларыннан берсеннән-берсе шомлы хәбәрләр килә башлагач, Караболак халкы тынып калды, хәвефкә төште. Ул тирәдәге авылларны, төбе-тамырлары белән кубарып, әллә кайларга илтеп ташлый башлаганнар икән! Имеш, ул База дигәннәренә җир җитми икән, Караболак халкы гомер буе утын әзерли торган Кыштым леспромхозын да үзләренә алганнар, бөтен җиргә тимерчыбык тарттырганнар, мылтыклы солдатлар куйганнар, дип сөйлиләр. «Кызылташ», «Доброволец», «Беренче май», «Красный луч» колхозларын, авыллары, халкы белән бергә, башка урынга күчергәннәр икән, совхозларны, ул тирәдәге әртилләрне бетергәннәр, ди. Иртәштәге ул җир асты шәһәре шулхәтле зур булачак икән, бу тирәдәге авылларга хәтле килеп җитәргә мөмкин, ди. Әле Караболакны да күчерергә мөмкиннәр икән, заводка җир җитмәсә. Инде ничә авылны кузгатканнар, туздырып ташлаганнар, ди, чиратта Караболак икән.

Берсеннән-берсе шомлы бу хәбәрләрдән, имеш-мимешләрдән Караболак халкы өркеп калды. Җитмәсә, гомер булмаганны, авылга милиционерлар һәм махсус күзәтчеләр билгеләделәр, алар Караболактагы һәр үзгәрешне, һәр йорттагы хәлне районга җиткереп торырга тиешләр иде. Бу хәлләрнең барысы да Иртәштәге төзелеш белән бәйле икәнлеген инде күпләр аңлый башлады. Ул арада авылга эшче көчләр җыярга вербовщиклар килеп җитте, алар ир-егетләргә җәннәт тормышлары вәгъдә итеп, Иртәштәге төзелешкә кодалыйлар иде. Караболак егетләренең күбесе бу кармакка капты, бәхет эзләп, Иртәшкә чыгып киттеләр, һәм күбесе беркайчан да яңадан авылга әйләнеп кайта алмады. Чөнки 1947 елдан

башлап, Иртәштәге База төзелешенә кергән кешеләрне зонадан бөтенләй чыгармый башладылар, хөкүмәтнең карары шундый иде. Кая анда атна саен авылга кайтып йөрүләр, аларны ата-аналары, туганнары үлгәч күмәргә дә Иртәштән читкә чыгармадылар. Язган хатлар барысы да ачып укылды, артыгын ычкындырган кешеләр шунда ук хөкем ителде һәм алар юкка чыктылар. Чөнки яңа гына тагы Иртәштәге атом төзелешенә килеп киткән Лаврентий Бериянең әмере шундый иде. Бирегә кергән, яшәгән, эшләгән кеше егерме биш ел буе Иртәш турында беркемгә берни сөйләмәскә дип, махсус документларга кул куя иде. Беренче совет атом бомбасын ясау коточкыч дәүләт серенә әйләнде.

Әлбәттә, Караболак халкы аларын ук белмәде, әмма сугышта булган, җитәкчелектә эшләгән ир-атлар шактый нәрсә сизенәләр иде. Нәбиулла да эшнең кайсы якка баруын чамалый башлады, чөнки Коншакта да анысын-монысын ишетеп кайта, халык та сөйләп тора. Шулхәтле серлелек, тыюлар бары тик хәрби эшләр белән генә бәйле булырга мөмкин. Ә кайда хәрбиләр — анда корал, анда сугыш, анда үлем. Сугышларны күргән Нәбиулланың туган авылы, гаиләсе, яңа туган кызы өчен җаны борчылды, күңелен шом басты. Тыныч түгел иде Нәбиулланың күңеле, чөнки Караболакта, бөтен тирә-якта ниндидер шом, афәт йөри кебек иде. Урал аръягында меңнәрчә еллар үз җайлары белән яшәп яткан татар авылларының асты өскә килә, кайсын, көчләп, башка урынга күчерәләр, кайсының бөтен ризыгын мәҗбүри алып чыгып китәләр, ир-атларны җыеп йөриләр. Шуның өстенә, гомер булмаганны, әллә нинди шымчылык, шикләнү, әләк, яла ягулар башланды, ялган китте. Кем килгән, кем киткән, каян килгән, кая киткән — болар барысы да авыл советына язып бирелергә тиеш, өстән әмер шундый. Авылда артыгын эшләү түгел, артыгын сөйләү дә куркыныч була башлады. Ә халык сорый, йөдәтә, авылны тагы имеш-мимеш, шик баса.

Әмма Нәбиулла өчен иң авыры әле бу түгел, ә авылдан сөрелергә тиешле кешеләрнең язмышлары булып чыкты. Коншакка җыеп тагы әйттеләр: 1947 елның август аенда хөкүмәт шундый карар чыгарган — База төзелеше тирәсендәге режим зонасыннан бөтен ышанычсыз кешеләрне чыгарып бетерергә кирәк икән. Ягъни шушы 99 авылдан кем моңа кадәр җинаятьтә гаепләнеп хөкем ителгән, төрмәдә утырган — барысын да бу тирәдән сөрергә, куарга кирәк булачак. Бөтен нәселләре белән, ягъни үзләрен, туганнарын, балаларын. Болар җәмгысе тирә-якка 1116 гаилә җыела икән, ягъни 2939 кеше, шуларның 746сы — балалар. Куылырга тиешле берничә гаилә Караболакта да бар булып чыкты. Бу эшләрне

оештыру белән район үзәге Коншак кына түгел, Чиләбе үзе шөгыльләнә икән, Мәскәүнең аерым күзәтүендә тора, дип тә кисәттеләр. Нәбиуллага хәтта сөрелергә тиешле кешеләрнең исемлеген дә бирмәделәр, бары тик атлар әзерләргә генә куштылар. Караболак элек-электән ышанычсыз авыл булгангамы, алдан белдерсәң, сөрелүчеләр качып бетәр, дипме, Нәбиуллага бары тик бу эшнең вакытын гына әйттеләр. Хөкүмәтнең гаять мөһим бу карары үтәлүен өзсә, Нәбиулланың үзен дә, сөрелүчеләрне дә трибунал көтәсен кисәттеләр. Караболакның ышанычсыз кешеләрен илдән сөрү 1947 елның кара көзенә билгеләнде.

Бу хәбәрне алып кайткач, Нәбиулла төне буе йоклый алмады. Кемнәрне Караболактан сөрергә җыена соң Чиләбе комиссиясе? Нигә аны шулхәтле зур сер итеп саклыйлар, хәтта авыл советы рәисенә дә алдан әйтмиләр? Кайчандыр эшләгән җинаять өчен сөрәләр икән, бу сугыш чоры гамәлләренә туры килә инде, ул вакытта авылда булган хәлләрне Нәбиулла бөтенләй белми. 1937 елда Караболактан чыгып киткәндә, Нәбиуллага әле егерме яшь тә юк иде, шул чыгып китүдән ул авылга 1945 елның көзендә генә кайтып керде. Шул арада Караболакта кемнәр нәрсә эшләгән, нәрсә өчен утырган яки утыра — ул үзе дә белеп бетерми әле.

Шул чагында аның йөрәге жу итеп китте. Тукта, немец әсирлегендә булганнар да шул ышанычсызларга керәме икән? Аның күршесе Якуп та бүгенге көндә Себер төрмәләрендә утыра бит, хәзер аның гаиләсен ни көтә? Якупның бар гаебе — әсирлектә булу. Ул вакытта әсирлеккә Нәбиулла үзе дә эләгергә мөмкин иде бит, алар Якуп белән янәшә генә иделәр... Нәбиулла һаман оныта алмый — 1942 елның кышында, Ленинград өчен барган каты сугышларда, алар чолганышта калдылар. Чолганышта калганнар арасында берничә татар, шул исәптән Нәбиулланың Караболактагы күршесе Якуп та бар иде. Якуп — Нәбиулладан берничә яшькә олы, сугышның беренче көненнән ут эчендә йөри икән. Аларның бу үлем кырында очрашулары бер могҗиза булды, ә аерылулары — иң зур фаҗига. Сугышка киткәч, Якупның Караболакта беренче баласы туган, ул Нәбиуллага гел шул турыда сөйли иде, гомерендә бер тапкыр күрмәгән шул баланы сагынып үлә иде.

Чолганышта калгач та, телендә соңгы сүзләре шул булды:

— Күрше, әгәр исән калсаң, Фәргать улымны ташлама, — диде ул. — Безнең язмыш хәзер билгеле түгел, Алла кулында...

Нәбиулланың сул кулы чәрдәкләнгән иде, Якуп аны, үз күлмәген ертып, кысып бәйләде.

— Болай үлем көтеп ятып булмый, якташ, мин үзебезнекеләрне эзләп китәм, — диде ул аннан соң. — Сиңа ярдәм алып киләм, шушы урында көт...

Шул китүдән Якуп башка әйләнеп кайтмады. Каны агып, әҗәл көтеп яткан Нәбиулланы, нинди дер могҗиза белән, санитар кызлар килеп эзләп тапты. Аларга, чыннан да, Якуп хәбәр итеп өлгергән, ә үзе, ак кар өстенә төшкән утлы күмер кебек, юкка чыкты. Аның ул вакытта адашып әсирлеккә эләгүен, өч ел гомерен немец пленында уздыруын Нәбиулла Караболакка кайткач кына белде. Якупны әсирлектән совет армиясе коткара, әмма шул ук совет власте аны, туган авылына да кайтарып тормыйча, бер әсирлектән икенчесенә — ун елга Себер лагерьларына озата... Шулай итеп, үзе сугышка киткәч туган улын бер тапкыр да күрмичә, күршесе Якуп тагы әсирлеккә эләгә.

«Аларны да алырлармы икәнни?» — дип уйлады Нәбиулла, бик нык борчылып. Якупның карт ата-анасы, энесеңелләре, хатыны, улы Фәргать аның күз алдына килеп басты. Әллә төнлә кереп кисәтергәме икән? Ә кая барсыннар алар бу кара төндә, карлы-яңгырлы кара көздә? Бәлки әле аларга кагылмаслар да, Нәбиулла юкка гына шулай борчыладыр? Ул карт-карчыктан, бала-чагадан, хатын-кыздан авылга, Иртәш төзелешенә нинди зыян булырга мөмкин? «Юк, совет власте бу эшкә бармас, — дип уйлады Нәбиулла. — Андый заманнар үтте бит инде...»

Иртә белән бераз яктыруга авылга хәрбиләр кереп тулды. Алар барысы да урыслар иде һәм араларында Нәбиулла белгән бер генә кеше дә юк. Хәрбиләрдән тыш Нәбиулла Чиләбедән килгән махсус комиссия әгъзаларын да күреп өлгерде, алар да барысы да урыслар иде. Иртәшкә терәлеп үк утырган Караболакка, усаллыгы белән тирә-якка даны таралган бу татар-мишәр авылына хәтта урыс генералы килүен дә күреп, Нәбиулла эшнең ни дәрәҗәдә җитди икәнлеген аңлады. Соңыннан белде Нәбиулла — генерал погонлы бу ыспай кеше Иртәштәге яшерен төзелешнең төп шымчысы Иван Ткаченко булып чыкты. Аның белән Чиләбедән өлкәнең милиция начальнигы Розов, исполкомнан Кудрявцев дигән кешеләр дә килгән иде. Әлбәттә, аларның төп эшләре Караболактан берничә гаиләне сөрү генә булмагандыр, моның өчен НКВД генералларының, Чиләбе түрәләренең авылга килүе кирәкми, бу эшне автоматлы солдатлар да үтәп чыга ала иде. Аларның ни өчен Караболакка килүләрен Нәбиулла еллар үткәч кенә аңлады, әмма ул вакытта Караболак фаҗигасен үзгәртерлек түгел иде инде.

Менә ул, НКВД генералы, теләр-теләмәс кенә машинасыннан төшеп, татар авылына карап тора. Авыл нык, хәлле күренә, каралты-куралар яңа, урам тулы бала-чага, боларны хәтта сугыш, ачлык та кырып бетерә алмаган. Әмма тиздән биредә барысы да үзгәрәчәк. Барысы да. Юк, авылдан сөре-

ләсе берничә гаилә турында ул уйламый да, аның өчен монда калучылары мөһимрәк. 1944 елда Кырым татарларын, чечен-ингушларны илләреннән сөрүдә башлап йөргән бу урыс генералы аннан Литваны канга батыра, шушы тырышлыклары өчен ул Суслов тарафыннан Уралга, атом төзелешенә җибәрелә. Ул менә бу татар авылында кортлар кебек кайнашкан кешеләрнең алдагы язмышларын бик яхшы белә. Бу авыллар, бу татарлар аның оешмасына дөньяда тиңе булмаган сынаулар үткәрү өчен кирәк. Әмма алар үзләре моны беркайчан белмәячәкләр, аларның бар эшләре туу, үрчү, үлү булачак. Шушы тәҗрибәләр аша аның иле дөньяның бөек серләренә ия булачак, атом-төш сугышы башланган очракта, исән калу юлларын өйрәнәчәк. Бу авылга, бу кешеләргә урыс генералы Иван Ткаченко бары тик тәҗрибә тычканнары итеп кенә карый.

Җыелып авыл советына кергәч, алар Нәбиулланың кулына исемлек тоттырдылар, куылучыларга җыенырга бер сәгать вакыт бирделәр. Нәбиулладан бары тик аларны ат-арба белән тәэмин итү генә сорала иде, калганына аны якын да җибәрмәделәр, бар эшне НКВД хәрбиләре үз кулларына алдылар. Бу эштә аларның тәҗрибәләре зур иде. Исемлеккә күз төшерүгә, Нәбиулла унлап гаилә арасында Якупларның да фамилиясен күрде. Калганнар кайсы бер уч ашлык, кайсы сугыш вакытында салым түли алмаган өчен утыртылган кешеләр иде. Алардан авылга бер зыян да юк, алар башкалар кебек үз хезмәтләре белән көн күреп яталар иде. Һәм беркем белән киңәшеп тормыйча, аларны авылдан сөрергә булганнар. Моны белгәч, Нәбиулланың бугазына төер утырды, күкрәгген ачу уты көйдереп узды. Авыл халкын бу хәтле санламау, мыскыл итү аны ярсып аягына бастырды.

— Бу кешеләрнең илдән сөрелерлек ни гаепләре бар соң? — дип сорады ул, комиссия әгъзаларына сөзеп карап. — Сугыш вакытында ачтан үлмәс өчен кырдан алган бер уч ашлык моңа сәбәпче була аламы?

Чиләбедән килгән комиссия әгъзалары алыптай бу авыл иренең сүзләреннән башта өнсез калдылар. Аларга Караболак авылы халкының усаллыгы турында кат-кат әйткәннәр иде. Алдыңа-артыңа карап йөрмәсәң, монда урам уртасыннан юкка чыгуың да бар икән. Кисәтүләре дөрес булып чыкты, инде авыл советы рәисләре шундый булгач, башкалар турында ни әйтәсең? Хөкүмәт карарын шик астына алу өчен куш йөрәкле булу кирәк. Ә бу татар әнә, ярсыган үгез кебек, боларга карап каткан. Әгәр эшне тиз тотмасаң, монда фетнә күтәрелергә дә бик мөмкин. Кайда диген — атом төзелешенең борын төбендә! Мондый хәлне Мәскәүдә генә түгел, чит илләрдә дә тиз ишетәчәкләр, төпченә, казына башлаячаклар. Ә бу хәл бер дә атом-

чылар файдасына түгел. Әлбәттә, урам тулы НКВД солдатлары, корал белән боларны бик тиз бастырырга була, әмма тавыш чыгарырга ярамый. Димәк, бу бунтарьларны хәйлә белән алдырырга, мәкер белән бетерергә кирәк.

— Бу — хөкүмәт карары, безнең аңа буйсынмый хакыбыз юк, — диде НКВД генералы, тыныч булырга тырышып.

Чөнки аңа урамнан, капка төпләреннән йөзләгән, хәтта меңләгән кеше нәфрәт белән карап тора иде. Күпләрнең кулында — сәнәк, лом, балта... Мөгаен, сөрелүчеләр турында хәбәр авылга таралып өлгергәндер, кешеләр берәм-берәм дә, төркем-төркем дә авыл советы бинасы янына җыела башладылар. Аларга каршы НКВД солдатлары тезелеп басты, ике яктан бер саксыз хәрәкәт булса да, бөтен авыл, шул исәптән Ткаченко үзе дә ут астында калачак иде. Үткенрәк мишәрләр авыл советына да кереп тулдылар, алар Нәбиулланың сүзен, әмерен көтәләр иде.

— Мин бу эшне үти алмыйм, — диде Нәбиулла, кара исемлекне комиссия әгъзалары алдына куеп. — Мин моның өчен сигез ел солдат хезмәтендә йөрмәдем. Мин үз халкымны авылдан куу өчен Гитлер белән сугышмадым. Дөрес хәл түгел бу.

Ишек төбендәгеләр дә шаулашып алдылар. Халык соңгы вакытлардагы чикләүләрдән, талаулардан, билгесезлектән тәмам туйган иде, инде авылдан ук сөрә башлагач, елеккеге гадәт буенча күпләр сәнәккә тотынды. Әлбәттә, НКВД генералы теләсә, аларны минут эчендә бастыра ала, әмма аңа гауга кирәкми. Иртәш телгә керергә тиеш түгел. Аннан, аның эшемени ул — авыл мужиклары белән сугышып йөрү? Алар болай да үзләренә кирәкне алачаклар, аларның монда калулары кирәк. Югыйсә Ткаченко аларны бөтен авыллары белән бер көн эчендә Уралтауның теге ягына илтеп ташлый ала, әмма алар өчен җәһәннәм менә монда әзерләнгән.

— Сез беләсез, хәзер бу тирәдә зур төзелешләр алып барыла, — диде ул, ишек төбендә өелешеп басып торган авыл ирләренә карап. — Сугыштан соң промышленностьны күтәрергә кирәк, илгә тракторлар, машиналар, комбайннар кирәк, күп кирәк. Шуңа күрә ул заводлар инде Урал аръягында да төзелә башлады. Шуңа күрә без заводлар төзеләчәк җирләрдәге күп кенә авылларны башка урыннарга күчерәбез. Ул исемлектә сезнең авыл да бар иде, әмма халыкның күплеген искә алып, без аңа кагылмадык. Совет властена каршы булган берничә гаиләне генә бу удар төзелешләр булган урыннан башка җиргә күчерергә булдык. Әмма без бу фикеребезне үзгәртә дә алабыз, бүген бу гаиләләргә кагылып тормыйбыз, иртәгә бөтен авылыгызны Уралның теге ягына күчерәбез. Сез шуңа ризамы?

Халык дәшмәде. Беркем дә мәсьәлә болай куелыр дип көтмәгән иде. Һәркем үзе турында, үз гаиләсе, балалары язмышы хакында уйлады. Караболактан башка алар тормышларын күз алларына да китерә алмыйлар иде.

— Алайса, авыл халкына менә шуларны чыгып аңлатыгыз хәзер, — диде Ткаченко, эшне һаман үз җаена борып. — Һәм тыныч кына өйләрегезгә таралыгыз. Безгә хөкүмәт карарын үтәргә мөмкинлек бирегез.

Авыл ирләре бер Нәбиуллага, бер урыс генералына карадылар. Нәбиулла дәшмәде, чөнки ул күп кенә татар авылларының төзелешкә җир җитми дигән сәбәп белән башка урынга күчерелүләрен белә иде. Ә күчү — ул инде таралу, бетү, Караболакны бөтенләй тузгытып ташлау булачак. Авыл халкы моның өчен Нәбиулланы кичермәячәк. Димәк, аз корбаннар биреп булса да, Караболакны саклап калырга кирәк, авылга тидермәскә. Шуңа күрә ул ишек төбендәге ирләргә берни әйтмәде, карашын читкә борды. Ирләр киңәшергә урамга чыгып киттеләр.

Ткаченко исемлекне алып, авыл активистларына тоттырды. Өлкәнең башкарма комитетыннан килгән түрә Нәбиулладан пичәтне сорап алды, милиция начальнигы исә аны бер читкә алып барып утыртты, янына кораллы ике сакчы куйды. Коммунист һәм комсомоллар, сөрелүчеләр исемлеген алып, авыл буйлап чыгып киттеләр. Аларга баштанаяк коралланган НКВД гаскәре иярде. Ткаченко төркеме урамга чыгып бу хәлләрне күзәтеп торды, алар бар яктан да кораллы сакчылар белән уратып алынган иде.

Куылырга тиешле һәр капка төбенә, кораллы хәрбиләр озатуында, җигүле ат-арба килеп туктады. Кешеләргә кирәк кадәр әйберләрен җыярга, бала-чагалары белән арбага чыгып утырырга бер сәгать вакыт бирелгән иде. Авыл өстендә тавыш, гарасат купты. Кемдер кычкырып елый, кемдер каядыр йөгерә, карлы-яңгырлы пычрак урамга чүпрәк-чапрак, төенчекләр коела, мал-туар үкерә иде. Сөрелүче һәр йортны хәрбиләр сырып алган, мылтык көпшәләрен һәркемгә төбәп, алар атып җибәрергә әзер торалар. Ул арада каяндыр ашыгыч хәбәр алып, авылга тагы өч йөк машинасы хәрбиләр кереп тулды, Караболак камалышта калган кебек булды. Кешеләрнең котын алып, авыл өстендә хәрби самолет очып йөри башлады. Аның тавышыннан, колакларны ертып үкерүеннән арба артына бәйләнгән сыер маллары, бауларын өзеп, авыл буйлап чабып киттеләр. Караболакта мәхшәр купты...

Бер Караболакны гына түгел, бөтен Кырымны сәгать эчендә сөргенгә сөргән Иван Ткаченко бу юлы да җиңде — өйлә турында унлап олау Чиләбе юлына карап кузгалган иде.

Алар кебекләр өчен анда 300 тимер юл вагоны әзерләп куелган һәм бу ышанычсыз кешеләр Урал аръягына — Златоуст, Миасс, Сатка тирәсенә сөреләчәкләр иде. Аларга беркайчан да атом төзелеше тирәсендәге шәһәр һәм авылларда — Чиләбедә, Магнитогорскийда, Карабашта, Кыштымда, Уфалейда, Коншак, Кузнецкий, Кәсли һәм Аргаяш районнарында яшәргә рөхсәт ителмәс. Шулай итеп, әле ясалып та өлгермәгән атом бомбасы меңләгән кешене көчләп нигезеннән кубарыр, оясын туздырыр, туган якларыннан аерыр. Шушы атом аркасында меңьеллык татар авыллары үзләренең иреклә-рен югалтырлар, мәңгегә органнар күзәтүе астында калырлар. Әмма бу хакта әле куылганнар да, калганнар да берни белми.

Унынчы арбада, әнисе итәгендә, төрмәдәге Якупның бишалты яшьләрдәге улы да утыра. Ул әле кая барганын, ни өчен барганнарын аңламый, аның бары тик күрше кызы Гөлҗиһан янына кереп, шул матур бала белән уйныйсы килә. Нәбиулла абыйсының атына печән ашатасы килә, урам малайлары белән авыл янындагы тау куышларында качыш-качыш уйныйсы килә. Ә аны, арбага утыртып, әллә кая алып баралар. Әнә, тәрәзәгә капланып, аңа карап калган күрше кызы Гөлҗиһан да ераклаша, Караболак та әкренләп артта кала, тау куышлары да күздән югала. Фәргатьнең, арбадан сикереп төшеп, яңадан авыл ягына йөгерәсе килә, әмма янда мылтыклы абыйлар утыра. Алар булмаса, Фәргать инде күптән Гөлҗиһаннарда булыр иде, алар икесе бергә мич башына качарлар иде, аларны беркем эзләп таба алмас иде. Хәтта менә бу мылтыклы абыйлар да. Фәргать алардан курка һәм башын тизрәк әнисенең бишмәтенә төртә. Сверлау борылышын узгач, инде Караболак та күренми башлый, эңгергә төренеп, бөтенләй күздән югала. Авыл ягына каерылып-каерылып караган кешеләрнең, карлы яңгырга кушылып, битләреннән ачы күз яшьләре ага. Чөнки Караболак кала бит, Караболак кала, ургып аккан елгалары, саф чишмәләре, серле күлләре, борынгы зират-курганнары, Аллакүле, тау куышлары белән Караболак кала. Арбаларга беркайчан да авылдан чыкмаган 80—90 яшьлек карт-карчыклар, яңа туган сабый балалар, сугыш гарипләре, хатын-кыз төялгән. Карт-коры эчтән генә Коръән укый, тәкбир әйтә, Караболак белән бәхилләшә. Хатын-кызлар, соңгы тапкыр авыл өстенә карап, күңелләреннән мөнәҗәт әйтәләр, Караболак белән бәхилләшәләр. Көзге бозлы юлда, Чиләбе ягына карап, атлар бара, язмыш арбасына татар халкы төялгән. Караболак урманнары, Биташ күлләре аларны дога һәм мөнәҗәт белән озатып кала...

Атамның бер гөле идем,
Анамның былбылы идем,
Бу хәсрәткә гаҗиз булдым,
Сабыр бирсен үзе Аллаһ...

Эчемдә кайгылар тулды,
Йөземнең нурлары шиңде.
Йөрәгемдә кайгы тулды,
Сабыр бирсен үзе Аллаһ...

Үләр идем, үләр хәл юк,
Бу хәлләргә түзәр хәл юк.
Киңәш итәр кешем дә юк,
Сабырлык бир үзең, Аллаһ...

Сабырлыкның сабакларын
Китаплардан караганнар.
Сабыр иткән кешеләрне
Шәһитләр дип санаганнар...

## Дүртенче бүлек

Караболак...

Татар Караболагы...

Каралып, ургып аккан елгасы да шул исемдә, авылы да... Дөрес, янында Урыс Караболагы да бар, әмма алар да Караболак елгасы буенда булганга авылларына шундый исем биргәннәрдер...

Караболак елгасын элек бик киң, тирән сулы елга булган, диләр, аның аргы ягына кешеләр түгел, атлар да йөзеп чыга алмаган, чөнки агым бик көчле булган. Суының шундый кара-кучкыл төстә булуы аның төбендәге кара ләмнән икән, ә болай бик чиста сулы елга ул Караболак. Авыл халкы үзе дә суны шуннан эчә, мал-туарына да шуннан ала, гомер буе шул су бәрәкәте белән яши. Дөрес, авыл янында гына Аллакүл чишмәсе бар, аның суын халык бары тик шифага гына тота, олы як аны өшкереп эчә. Татар Караболагы авылы халкы үзенең алыптай озын буйлы, озын гомерле булуы белән бөтен тирә-якта аерылып тора, биредә йөз яшьтән узучылар да шактый. Баһадир гәүдәле Караболак татарлары үзләренең усаллыклары белән дә дан тоталар, әмма бу явыз усаллык түгел, гадел турылык, гаять үткенлек. Шуңа күрә Караболак халкыннан тирә-юньдә өркеп торалар, аларның чаялыкларын, елгырлыкларын мишәрлектән күрәләр.

Караболак элек-электән бай, матур яшәгән, үзенең тырышлыгы белән тирә-юньгә дан тоткан. Ул шулай ук бу якларда иң чиста авыл булып та саналган, биредә баскыч төбендәге ташларга хәтле ялтыратып юып куя торган булганнар. Шуңа күрә бу авылга читтән килен булып төшкән кеше зур

сынаулар узган, бик тырышлар гына монда яшәп кала алган. Караболак халкы усалдан саналса да, аның үзенең язылмаган кануннары бар, шуларның берсе — «Миңа тимә, мин сиңа тимәм» дигән шарт. Ягъни бу авыл халкы, үзенә тимәсәләр, кешегә кагылмаган, үзенә кагылсалар, җавапсыз калмаган. Мең еллар буе халыкта корычтай холык чыныккан, Караболак татарлары беркайчан да үзләрен җәберләргә ирек бирмәгәннәр. Бу авылда беркайчан да эчү, урлашу булмаган, бары тик читтән килгәннәр арасында гына шундый ямьсез гадәтләр күренә башлаган. Әмма бу авылда начар кеше озак яши алмаган, андыйларны куганнар. Гаять укымышлы, горур, һәр йортта китап булган Караболак татарларының көтүен дә Урал аръягыннан килгән күчмәннәр көтә торган булган. Караболак халкы, борынгы шәҗәрәләргә таянып, үзен Нух пәйгамбәр заманнарыннан калган Алып Ханнар нәселен дәвам итүчеләр дип санаган һәм шуларның яшәү рәвешенә тугры булып калган.

Заманында өяз үзәге булып торган, зур базарлары, мәктәпләре, дүрт-биш мәчете, укымышлы, галим кешеләре белән бөтен тирә-якка дан казанган бу татар авылы ничек барлыкка килгән соң чал Урал артында, кара урманнар эчендә, күлсазлыклар арасында? Нигә Караболак халкы үзенең кырыс холык-фигыле, алыптай гәүдә төзелеше, ханнарча яшәү рәвеше, зирәклеге белән бу якларда яшәүчеләрнең барысыннан да аерылып тора? Тарихчыларның язуы буенча, бу авыл 1553—1554 елларда, Явыз Иван Казан каласын басып алгач, Идел-Чулман буйларыннан качып киткән татарлар тарафыннан салынган икән. Авыл көнен, Караболак тарихын шулай билгеләп үтәләр дә. Картларның сөйләвенчә, башта бирегә Муса исемле кеше килеп урнашкан, ул тирә хәзер Торчак дип, ә Караболак авылының ул ерак башы Мусакай дип атала. Мусаның Бәйрән (Бәйрәм) исемле улыннан — Әбделмән, аннан — Фәйзулла, аннан — Сәйдулла, аннан — Хәбибулла, аннан — Әсәдулла, аннан Шәрәфетдин туа. Алар янына Зөлкарнәйләр, Уразайлар нәселе килеп кушыла. Шулай итеп, 450 ел вакыт эчендә дүрт-биш мең кешелек зур татар-мишәр авылы барлыкка килә. Моны рәсми тарихчылар яза.

Әмма...

Әмма Караболак күпкә, бик күпкә карт авыл ул. Ул гына да түгел, хәтта зур тарихчылар да җавап таба алмаган борынгы курган, кирмәннәр иле ул Караболак тирәләре. Картларның сөйләве буенча, монда элек иксез-чиксез диңгез җәйрәп яткан. Бөтендөнья туфаныннан калган зур су булган ул. Ул заманда бу тирәдә кешеләр бары тик Уралтау башларында гына исән калганнар, шунда гына яшәгәннәр, чөнки аның түбәсенә су менеп җитә алмаган. «Без Нух пәйгамбәр-

нең улы Яфәстән таралган нәсел», — дип сөйли торган булган Караболак картлары. Алар Нух пәйгамбәр көймәсенең Урал тауларына туктавы турында буыннан буынга сөйләп калдырганнар. Моннан 100 мең еллар элек, әле таш гасырларда ук, алыптай гәүдәле ул кешеләр Урал тауларыннан түбән төшәләр һәм дөнья буйлап тараламар. Караболактан ерак түгел Аллакүл дип аталган бер хикмәтле күл бар. Картларның сөйләве буенча, Уралтаудан төшкән Алып кеше шунда Аллага үзенең беренче гыйбадәтен кылган, таш өстендә аның галәмәт зур аяк эзләре уелып калган. Күл тирәли уникe таш сын тезелешеп баскан булган, хәзер алардан инде таш өемнәре генә утырып калган. Кайберәүләр аларны ташка әйләнгән кешеләр, ди. Алар арасында иң зур сынны Әбиташ дип йөртәләр, халык исә, үзенчә кыскартып, Биташ дип тә атый. Күлнең исемен дә кайчагында шулай дип йөртәләр. Әбиташ, чыннан да, зур гәүдәле хатын-кызга охшаган һәм ул йөзе белән Иртәш ягына карап тора. Бәлки, анысы Иртәш тә түгелдер, Ирташтыр, әмма халык, үзенә җайлап, хәзер шулай дип йөртә. Әбиташ янында шактый зур җир куышы — мәгарә бар, аннан бик шифалы чишмә агып чыга, Караболакның олылары, кай төшләре авырса да, шуны өшкереп эчәләр. Мәгарә диварларында элек казанда аш пешерүче зур гәүдәле хатын-кыз рәсеме дә ясалган булган, хәзер анысын бары тик шәйләргә генә була инде.

Галимнәрнең язуы буенча, моннан дүрт-биш мең ел элек үк биредә яшәүче халык бакыр һәм тимер серләрен белгән, алардан эш һәм сугыш кораллары ясаган. Бу хакта Караболак янындагы курганнардан табылган борынгы әйберләр сөйли. Ул борынгы кешеләр биредә кирмән-калалар салып яшәгәннәр. Караболак янында гына биеклеге биш, киңлеге ун метр озынлыкта булган борынгы курган бар, Чиләбе, Мәскәү галимнәре аны скиф каберлеге дип билгеләп китәләр. Караболак картлары аны гомер буе изге урынга санаганнар, безнең борынгы бабабыз Алып Хан рухына дип, догаларын кылганнар. Халык сөйләве буенча, бу тирәләр, Нух пәйгамбәр нәселе күмелгәнлектән, изге җирләр санала икән. Караболак халкы инде мең еллар ислам динендә булса да, әллә кайдагы тамырлардан, әллә кайдагы тирәнлекләрдән әллә нинди гореф-гадәтләр дә килеп-килеп чыга. Мәсәлән, авыл халкы бу тирәләрдә кешегә авыр вакытларда ярдәмгә килә торган изге затлар яшәвенә чын күңелдән ышана. Аларны биредә Яхшылар дип атыйлар, күзгә күренми торган бу затларны намаз картлары, Аллаһның фәрештәләре, ди, кайберәүләр иялар дип йөртә. Алар өч сүздән артык әйтмиләр икән, кешене уятып, бәла-каза буласын кисәтәләр, ди. Һәрхәлдә, Караболак халкы шулай сөйли һәм ул моңа ышана.

Шушыларга карамастан авыл халкы бик дини, җәйге челләләрдә дә уразасын калдырмый, тыелган заманнарда да качып намаз укучылар була. Бигрәк тә олы як һәм хатын-кызлар дин-ислам чикләреннән чыкмаска тырышалар, мөселманча киенеп, мөселман ризыгы белән тукланалар. Ирләр исә дингә алай ук ябышып ятмый, әмма теге заманнарда гаетләрдә Караболакның дүрт-биш мәчете дә шыгрым тулы була иде, дип сөйлиләр. Патша заманында да иманында нык торган Караболак халкын совет власте шактый йомшарта, диннән биздерә. Бигрәк тә авылга читтән килгән халык, укытучылар, коммунист-комсомоллар, урыслар һәм башкортлар Караболакка үзләренең бәйрәмчә яшәү рәвешләрен кертеп өлгерәләр. Сугыштан соң дин инде йортларга куып кертелгән була, ул аерым гаиләләрдә генә сакланып кала.

Караболакта бик борынгы бер гореф-гадәтнең яшәп ятуын да әйтеп үтәргә кирәк. Ул — кот койдыру. Кайдан, кайчан килгән гадәт бу — монысын беркем әйтә алмый, әмма аны барысы да белә, кирәк тапканда, күпләр кот койдыра. Кеше бик нык куркытылганда яки үлем чире белән ятканда баралар бу адымга. Һәр заманда Караболакның кот койдыра торган үз карт-карчыгы була, шулай да бу эшне күбрәк хатын-кызлар башкара. Соңгы бер гасырда исә авылда кот коючы булып 110 яшьлек мишәр карчыгы йөри. Ул авырган кешене башта Коръән аятьләре белән өшкерә, аннан үзе генә белгән «кот догасын» укый, аннан шапылдатып, авыруның арка-күкрәкләренә суга башлый. Монысы халык телендә «шапылдату» дип атала. Әгәр бала бик нык курыкса, сөйләшә алмас хәлгә килсә яки тотлыга торган булып калса, аны караңгы кара мунчага алып кереп, үзенә күрсәтмичә генә өстенә кара тавык утырталар. Кара тавык кычкырып җибәрә дә, имеш, бала да куркып кычкырып җибәрә. Шушы каты курку аша чыккан коты аңа яңадан керә, имеш. Әлбәттә, бу эшләр муллалардан яки укытучылардан качып кына эшләнә, чөнки дин дә, фән дә мондый алымнарны кабул итми.

Караболакта шулай ук яңа туган баланы, биләүсәгә төреп, ипи калагына утыртып, уты сүнгән зур мичкә кертеп ала торган булганнар, шулай итеп, аңа да «кот койдырганнар». Баланың елап бүсере чыкса, аякның баш бармагы белән баланың кендегенә өч тапкыр баса торган булганнар, бу хәл өч тапкыр кабатланган. Күз тигәннән, сихердән, җеннән дә Караболакның үз догалары, үз дәвасы бар. Әмма халык күпчелек дәваны ислам диненнән, әбиләрнең мең төрле үлән-тамырларыннан, Караболакның шифалы суларыннан тапкан. Биташ күле тирәсендәге зәңгәр балчыкны халык тән яраларына сөрткән, суын җан яралары өчен кулланган. Һәм күпләр туксанга, йөзгә хәтле яшәгән, үзеннән соң ун-унбиш бала,

йөзләгән онык, зур нәсел калдырган. Авыл гариплекне, тилелекне белмәгән, таза агач кебек, тамырларын бик тирән җибәреп, гөрләп үскән дә үскән. Атом чорына ул менә шушы хәлдә килеп кергән.

Караболак халкының сөйләм теле дә тирә-юньдәгеләрдән шактый аерылып тора. Авылның исеменнән үк күренгәнчә, биредә төп халык татарлар яши, әмма аларның сөйләмнәрендә мишәрлек чатнап тора. Әйтик, алар кәгазьне мишәрчәләп, «кагиз», диләр, какны — «кагыт», пычакны «пыцак» дип сөйлиләр. Караболак халкы шулай ук җөмлә ахырында «кый» дип өстәп куярга бик ярата, «бардым кый», «кайттым кый» дип сөйли. Аларның тагы бер яратып куллана торган сүзләре бар — «дан» сүзе. Караболаклылар «яхшы булган» диясе урынга — «дан булган» диләр, «дан кеше» дип сөйлиләр. Алар әнине — «инәй», әтине — «атай», әбине — «нәнәй», бабайны — «карттай» дип әйтергә дә яраталар. Хәер, Урал аръягына Казан дәреслекләре белән килгән әдәби татар теле Караболак халкын да Казанча сөйләшергә өйрәтә башлады, ләкин юк-юкта «инәй», «нәнәй»ләр ычкынып китә әле, «кый» да ишетелеп ала. Караболак халкы бик җор телле, әйтем, шигырьләр белән сөйләп җибәрергә дә бик ярата һәм биредә һәркемнең үз кушаматы бар. Биредә «Аять ашлары» дип йөртелгән Коръән мәҗлесләре уздырырга бик яраталар, хатын-кызлар анда озаклап мөнәҗәтләр әйтәләр, белгән кеше Коръән укый. Һәм тагы бер гадәт бар — кеше үзе үлгәнче үзенә бәет чыгарып калдыра... Шулай дөнья белән, авылдашлары белән бәхилләшә, аларга соңгы сүзен әйтеп калдыра...

Менә шундый гаять үзенчәлекле бик борынгы авыл ул Татар Караболагы. Үз җирендә пәйгамбәрләрне һәм әүлияларны, ханнарны һәм каһарманнарны, борынгы скифларны һәм һуннарны яшәткән, тамырлары Атилла һәм Алтын Урда чорларына ук барып тоташкан авыл ул Татар Караболагы. Холкы һәм акылы белән барысыннан аерылып торган, ханнар нәселен дәвам иткән, кыпчак-мишәрлеген саклап кала алган авыл ул Татар Караболагы. Һәм заман ахырында атом аждаһасы белән берүзе йөзгә-йөз калачак авыл ул Татар Караболагы.

## Бишенче бүлек

1949 елның җәйге чиллә вакыты иде...

Ураза быел шушы вакытка туры килде, олы як, хатын-кызлар, хәтта балалар да уразада. Әмма мәктәпләрдә бик каты әйтелгән, өстән дә бик каты кисәтелгән — совет балаларын ураза тоттырмаска. Башка авылларда бу таләп бик тиз үтәлсә дә, Караболак халкын буйсындырып булмый, мәк-

тәптә барлык балалар да диярлек ураза тота. Читтән, бигрәк тә Уралның аръягыннан килгән укытучылар өчен бу хәл коточкыч булып күренә, шуңа күрә алар балаларны уразадан чыгару өчен барысын да эшлиләр. Җәй көне булуга карамастан, балаларны лагерьга җыеп, һәр иртәне рәтләргә тезеп куялар. Читтән килгән коммунист-комсомол укытучылар, кулларына сулы тимер кружкалар тотып, рәткә тезелгән балаларга көчләп су эчертеп йөриләр. Эчмәгәннәрнең ата-аналарын авыл советына чакыртып, теге вакыттагы кебек Урал аръягына сөрү белән куркыталар. Шуңа күрә олылар уразада булуларын яшерергә тырышалар, иртән сәхәрне дә тәрәзәләрен томалап кына ашыйлар, кичен авыз ачуларын да кешедән яшерәләр. Караболак халкын бер яктан атомчылар кысса, икенче яктан атеистлар аларның җаннарына тиеп тора. Шулай итеп, совет власте халыкның мең еллар буе алып барган тормышына, тәртибенә үз тамгасын сала, аңа үз яшәү рәвешен көчләп тагарга тырыша. Халык бу хәлләргә үзенчә каршы тора, әмма күпләр моның белән ризалашырга мәҗбүр була, чөнки һәркемнең проблемасыз, тыныч яшисе килә.

Гөлҗиһаннар өендә дә уразаны качып тоталар. Аның карттай-нәнәе дә, атай-инәе дә ураза тоталар, Гөлҗиһанның иң яраткан бабасы — Таһирҗан бабай да ураза тота. Ул әле бабай да түгел, җир җимертеп, тракторда эшләп йөри, әмма кечкенә кызчык Гөлҗиһан аны, яратып, бабай дип атый... Гөлҗиһан үз яшенә күрә түгел, гаҗәеп тере, зиһенле бала булып чыкты, бөтен урамны, күрше-тирәне исемнәре белән белә, инде укый-язарга тырнаштыра, кызыксынмаган нәрсәсе юк. Гөлҗиһан әле кечкенә, ул ураза тотмый, әмма һәр көнне олылар белән сәхәргә торып утыра, кичен олылар белән бикләнеп авыз ача. Ул күп вакыт каршыда гына яшәүче карттайларында була, шунда йоклап та кала, кайсы көнне әтисе кайтып җитеп, аны кулларына күтәреп, үзләренә алып чыгып китә. Гөлҗиһан әтисен барысыннан да нык ярата, хәтта Таһирҗан бабасыннан да артык. Хәтта әнисеннән дә. Юк, икесен тигез ярата Гөлҗиһан. Алар да аны кулларында гына күтәреп йөртәләр.

Гөлҗиһанның әтисе хәзер авыл советында эшләми, аны теге вакытта чыгарганнар. Авыл халкы дәррәү күтәрелеп якламаса, бәлки, аны утыртып та куйган булырлар иде. Караболак халкы Иртәш төзелешенә эшче һәм ризык бирмәү белән яный башлагач кына, органнар Нәбиулланы тынычлыкта калдырды. Бәлки, аны сугышта алган орден-медальләре күп булу коткарып калгандыр, бәлки, яралы-гарип булуы. Әлбәттә, бу хәлләрдән соң Нәбиулланы эштән һәм партиядән чыгардылар, әмма грамоталы кеше буларак, аны ферма

мөдире итеп куйдылар. Гөлҗиһанның әтисе, нәкъ элеккеге кебек, иртән караңгыда чыгып китә, кич караңгыда кайта. Аның әнисе дә көне буе кырда, көне буе колхоз эшендә. Шуңа күрә Гөлҗиһанның күп вакыты әби-бабасы янында уза, алар, Караболак гадәте буенча, янәшәдә генә яшиләр.

Ә Караболакта гадәт шундый — биредә малай өйләнгәч, аны башка чыгаралар, ягъни үзенә йорт салып бирәләр. Аңа бөтен нәсел, бөтен туган-тумача булыша, чөнки үз йорт-җире булган кеше генә биредә ир-ат санала. Кызларны яшьли кияүгә бирәләр, ир балаларны, өйләнгәч, аерып чыгаралар, ә төпчек малай ата-ана янында кала. Гомер буе шулай булган, халык хәзер дә шулай яшәргә тырыша, әмма заман бу тәртипкә дә үз төзәтмәләрен кертә. Караболак яшьләре хәзер авылда яшәүгә караганда, читкә китүне артыграк күрәләр. Кем укырга дип китә дә әйләнеп кайтмый, кем бәхет, эш эзләп чыгып китә. Күпләр хәзер кайсы Чиләбедә, кайсылары Сверлауда, Иртәштә, башка шәһәрләрдә. Әби-бабасының төпчек уллары Хәбибулла хәзергә мәктәптә укып йөри, әмма аңа да тиздән армиягә. Аннан авылга кайтырмы ул, юкмы — әлегә беркем белми.

Кичләрен авыз ачарга Гөлҗиһан һәр көн әби-бабасы янына керә. Менә бүген дә ул, кояш баер алдыннан, йөгереп аларга керде. Әбисе Нурҗамал табын әзерләп йөри, бабасы әнә, чәчәкле намазлыгын җәеп куеп, намаз вакытын көтә. Гөлҗиһан исә, тәрәзәгә капланып, зур, кызыл кояшның Караболак ярыннан тәгәрәп төшеп китүен күзли, чөнки әби-бабасы шул чакта гына өстәл янына утырачаклар. Юк әле, алар чеметеп тоз капканнан соң, башта намаз укыячаклар, аннан соң ашый башлаячаклар. Менә монысы Гөлҗиһан өчен иң кызык, иң күңелле вакыт, ул да алар белән иң тәмле әйберләрне авыз итә. Менә шуңа күрә Гөлҗиһан, тәрәзәгә капланып, бик тырышып кояшны күзәтә, ә ул һаман күздән югалырга ашыкмый. Менә ул инде Караболак елгасына якынлаша, менә яр читенә килеп җитә, анда тоньк утлар чәчеп, бераз эленеп тора, һәм менә... тәгәрәп, яр астына ук төшеп китә!

— Нәнәй! Карттай! Кояш суга төшеп китте! — дип кычкыра Гөлҗиһан бар көченә.

Бабасы: «Шулаймыни, кызым?» — дигән була, бармак башы белән генә чеметеп тоз каба да дога кыла. Әбисе дә шуны ук эшли. Гөлҗиһан исә барысын да җентекләп карап, сеңдереп тора, алар артыннан догалар кабатлаган була. Аннан алар, аллы-артлы басып, намаз укый башлыйлар. Гөлҗиһан исә, зур түземсезлек белән, аларның укып бетерүләрен көтә, өстәлдәге тәмле әйберләргә бик үреләсе килсә дә, үзен тыя. Менә әби-бабасы, намазларын укып бетереп, урыннарыннан кузгалалар. Менә алар ашыкмый гына өстәл яны-

на киләләр, ризыктан бигрәк, иң беренче эш итеп, сабыр гына чәйгә үреләләр. Әйтерсең алар көне буе ач тормаган, әле генә ашап кузгалган кеше кебек, һаман чәй эчәләр дә чәй эчәләр. Алардан узып, Гөлҗиһан тәмле әйберләргә үрелергә ояла, моны күреп, әби-бабасы аны кыстый-кыстый сыйлый башлыйлар. Әйтерсең ул монда иң зур кунак, иң кадерле кеше. Бу, бәлки, чыннан да, шулайдыр, Гөлҗиһан моны аңлап кына бетермидер. Гөлҗиһанга алар янында шундый рәхәт, аның мәңге-мәңге шулай яшисе килә. Әби-бабасы белән, әти-әнисе белән, беркая китмичә, гел Караболакта гына. Ул аның шулай буласына чын күңелдән ышана, чөнки алар авылында бөтен кеше шулай яши, барысының да инәй-нәнәйләре, атай-карттайлары бар.

Гөлҗиһан шулай дип уйлап өлгермәде, бөтен өй эче кинәт яктырып китте. Бөтен дөньяга — өйләргә, урамнарга, авыл өстенә әллә нинди көмеш нур таралды. Өй эче шулхәтле якты булып китте — Гөлҗиһан хәтта идән ярыгында кысылып яткан мәрҗәнгә хәтле күреп өлгерде. Нурҗамал карчык белән Ярулла карт ашаудан туктап калдылар, әсәрләнеп, төнге якты урамга карадылар.

— Күк кабагы ачылды! Аллаһның рәхмәте белән күк кабагы ачылды, теләк теләргә кирәк, — диде Ярулла карт, тизрәк намазлыгына тезләнеп.

— Күк капусы ачылды, балам, теләкләреңне телә, — диде әбисе, Гөлҗиһанны үзенә таба тартып.

Күк кабагы? Ә нәрсә соң ул — күк капусы? Гөлҗиһан аны аңламый, әмма аңа шулхәтле рәхәт, әйтерсең лә күктән төшкән ул якты нур Гөлҗиһанның күкрәгенә, күңеленә тула, тәнен иркәли. Колагына әллә нинди сәер моң ишелгән кебек була. Бу наз һәм моңнан Гөлҗиһанның хәтта елыйсы килә. Гөлҗиһан, бар дөньясын онытып, тагы тәрәзәгә каплана. Анда, яп-якты күккә карап, нигәдер этләр елый. Урам шулхәтле якты һәм тыныч, Гөлҗиһан туфракта үзенең көндез калдырган тәпи эзләренә хәтле күрә. Бу көмеш яктылыктан күк шундый тирән һәм ерак булып күренә, анда мәңге барып җитә алырлык түгел кебек. Гөлҗиһан соклануллы карашын тагы җиргә төшерә һәм урам буйлап бу якка таба йөгергән әнисен күрә. Колагында әбисенең сүзләре яңгырый — «Күк капусы ачылды, балам, теләкләреңне телә...»

Гөлҗиһанның гел-гел әнисе янында буласы килә, әтисе, әби-бабасы гел исән булсын, алар гел бергә булсыннар. Тагы нәрсә теләсен икән Гөлҗиһан? Әлбәттә инде, авыл гел булсын, Караболак мәңге-мәңге яшәсен.

Гөлҗиһан шулай дип уйлап өлгермәде, нурлы урамнан әнисе йөгереп килеп керде һәм кызын кочаклап алды. Аңа

да дөньяда шушы нәни кызы, бары ул кирәк! Ире, гаиләсе, шушы авыл кирәк. Ана белән бала, кочаклашып, могҗиза күргәндәй, төнге яктылыкка карыйлар. Аларга аннан моң коела, наз агыла, нур иңә. Әллә кайдан, әллә күктән, әллә җир астыннан, карт белән карчыкның пышылдап әйткән сүзләре ишетелә:

— Күк кабагы ачылды, ыланнар... Теләк теләп калыгыз...

Ул арада яктылык әкренләп сүнә, тарала башлый. Менә ул өй эченнән шуып чыгып китә, менә ишегалдыннан сыпылып урамга чыга, менә урамда күкләр белән тоташа да, эреп тарала. Көмеш нур Караболак өстендә бераз эленеп тора да, инде мәңгегә хушлашкан кебек, Урал таулары артына китеп югала. Авыл өстенә яңадан кап-кара төн килә... Өй эче кинәт кенә караңгыланып кала. Әбисе, капшана-капшана, сукыр лампаны кабызып җибәрә. Өй эчендәгеләрнең әсәрләнгән йөзләренә аның сүрән яктысы төшә.

— Әнкәй, нәрсә булды бу? — дип сорады Хәбирә, Гөлҗиһанны һаман кочагыннан чыгармыйча.

— Күк капусы ачылды, кызым, күк капусы, — дип җавап бирде Нурҗамал карчык, моңсу гына елмаеп. — Бу — Аллаһның рәхмәте инде... Мондый хәлне гомереңдә бер генә күрергә мөмкин, яки бөтенләй күрмәскә... Андый чакта теләк теләргә кирәк, балам... Теләкләребез кабул булсын инде...

— Бәлки, Аллаһның безгә бер-бер кисәтүе булгандыр бу, — дип әйтеп куйды Ярулла карт, әкрен генә. — Заман ахырының бер хәбәре... Таһирҗаннан сорарбыз әле, ул белә... Ни булса да, бик зур хикмәт инде бу, балалар... Аллаһның җиһан капкалары ачылды, анда кем нәрсә белән керә...

Өй эче тагы тынып калды. Стенадагы герле сәгатьнең тек-тек итеп йөрүе, өстәлдәге самавыр борыныннан чынаякка тып-тып итеп су тамганы гына ишетелеп торды. Бу гадәти, тыныч авазлар аларны яңадан җир тормышына — Караболакка алып кайтты. Алар, җәйге чиллә көне буе ураза тоткан кешеләр, шушы могҗиза сәбәпле, әле рәтләп ашап та өлгермәгәннәр иде.

— Әйдә, килен, безнең белән утыр, әле син авыз да ачмагансыңдыр? — диде Нурҗамал карчык, тиз генә өстәл өстен рәтләп. — Нәбиулла кайтмагандыр әле?

— Юк шул, бүген ерак җәйләүгә китте бит ул, — дип җавап бирде Хәбирә, өстәлгә якынрак килеп. — Бергә авыз ачарбыз дип көтеп торган идем, бу галәмәт башлангач, ничек монда килеп җиткәнемне сизми дә калдым... Дөнья бетә икән дип торам...

Алар шулай сөйләшә-сөйләшә, яңадан чәй эчәргә утырдылар. Сүзләре күк капусыннан яңадан Караболакка, Караболактан тагы үз хәлләренә кайтып төште. Күңелләре белән

дә, телләре белән дә барысы да Нәбиулланың кайтып керүен көтәләр иде.

— Исән генә йөри күрсен инде, — диде Нурҗамал карчык, барысының да уйларын сизгәндәй. — Теге елны тәмам котны алдылар бит, утыртып куя яздылар... Ураза икәнен дә бик сиздермәсен иде, төрле кеше бар хәзер авылда...

— Дөньясы әллә нәрсәгә әйләнде шул, — дип, сүзгә кушылды Ярулла карт та. — Караболакта гомердә мондый хәл булганы юк иде... Бөтенесе тыңлана, бөтенесе күзәтелә, бөтенесе әләкләнә...

— Авылга чит кешеләр кереп тулды, шуннандыр ул, — дип дәвам итте килене дә. — Мәктәбендә дә әллә кемнәр эшли, хәтта колхоз кырларында да әллә нинди вәкилләр, шикле кешеләр кайнаша... Кеше сөйли, болар барысы да шул Иртәштәге төзелеш белән бәйле икән... Атом бомбасы ясыйлар ди бит анда, халык шулай сөйли... Анда эшкә кергән кешене яңадан чыгармыйлар икән бит, Караболактан киткәннәр дә кире кайта алмаганнар...

Нурҗамал карчык, тиз генә урыныннан торып, тәрәзәләрне томалап килде, ишекне келәсенә элеп куйды.

— Кеше сөйләсә дә, син сөйләмә, килен, — диде ул, пышылдап кына. — Нәбиулла белән нәрсә булганын онытма... Алла сакласын, әнә Якупның гаиләсен нәрсә эшләттеләр бит...

Аларның шулай медер-медер сөйләшкәннәренә Гөлҗиһан эреп йокыга китте. Аны әле генә күктән төшкән көмеш нур чорнап-чолгап алды да, үзе белән күтәреп, югарыга алып менеп китте. Шул югарылыктан Гөлҗиһан Караболак өстенә карый икән. Аларның авыллары биредән нинди зур булып күренә! Караболак елгасы да әллә кайлардан башланып, әллә кайларга барып чыга икән. Әнә Гөлҗиһан әбисе белән җиләк җыя торган урманнар, чәчәкле болынлыклар, әнә серле Биташ күле. Биредән күлләр бик күп булып күренә, аларның берсе бетә, икенчесе башлана, барысы да зәпзәңгәр сулы. Алардан соң — кара урманнар, урманнардан соң биек таулар башлана. Алар шулхәтле күп, шулхәтле биекләр, Гөлҗиһан аларның очлы түбәләренә егылып төшүдән курка башлый һәм кирегә очып китә. Әнә аста, диңгез кебек зур күл буенда, бик күп кешеләр кайнаша. Алар шулхәтле күп, Гөлҗиһанның сабантуйда да бу кадәр халык күргәне юк. Анда әллә нинди биек-биек йортлар, шуларның берсендә Гөлҗиһан да яши икән. Ләкин ул инде бәләкәй Гөлҗиһан түгел, әнисе кебек, зур үскән икән, янында ниндидер балалар да бар. Бу Гөлҗиһанның үз балалары икән. Янында кара күзлекле ир-ат та бар, бу Гөлҗиһанның ире икән. Менә алар кинәт кенә барысы да юкка чыга, Гөлҗиһан тагы берьялгызы кала. Нигәдер аның бөтен җире авырта, шундый нык авыр-

та, сызлануга түзә алмый, Гөлҗиһан ыңгырашып куя. Шул арада күктән тагы яктылык иңә һәм Гөлҗиһанны югарыга күтәрә башлый. Инде Гөлҗиһанның бер төше дә авыртмый, аңа инде рәхәт, бик рәхәт. Ул, елмаеп, күзләрен ача — аны әтисе күтәреп алган икән бит!

— Бала җайсыз яткан, саташа.

Монысы әнисенең йомшак тавышы, Гөлҗиһан аны иң биек күктән дә ишетә, таный.

— Әйдә, чыгыйк, әнисе, бала өйдә йокласын...

Монысы — әтисенең көчле тавышы, Гөлҗиһан аны җир астыннан да ишетер, таныр иде.

Менә алар, кечкенә Гөлҗиһанны күтәреп, әкрен генә чыгып китәләр. Бу мизгелләрдә Гөлҗиһаннан да бәхетле, аның әти-әнисеннән дә көчле кеше дөньяда юк. Бу төнге авыл, җәйге йомшак җил, Караболак буеннан ишетелгән бака тавышлары, бакчадан килгән алма исе, төнге кошларның сайрап-сайрап җибәрүләре — болар барысы да аларның дөньясы, аларның байлыгы. Аңа хәзергә бары тик алар хуҗа.

Бу — нәни Гөлҗиһанның да яңа дөньясы. Иртәгә ул тагы шул су буена йөгереп төшәр, яшел чирәмнәрдә аунап уйнар, болынында — чәчәк, әрәмәдә — бөрлегән, урманнарда җиләк җыяр. Күк никадәр матур, нурга чумган булса да, Гөлҗиһан анда калмас, барыбер җиренә, Караболагына төшәр, бары тик шунда гына яшәр...

Караболак өстендә инде таң яктысы беленә. Гөлҗиһан әле белми — иртән бу җиргә йолдыз яңгыры явачак. Бу таңда ул әнисе белән сәхәргә дә тора алмас, күктән йолдыз яуганны да күрмәс. Бәлки, күрмәве хәерле дә булыр, чөнки күктәге йолдыз җиргә төшкәч, кара ташка әйләнә бит. Моны сабый күңеле барыбер аңламас, сыйдыра алмас, куркыр. Шуңа күрә ул төшләрендә булса да кичәге зәңгәр нур дөньясында калсын, җиһан капкаларыннан күккә менсен. Чөнки бу капкалар аның өчен ачылган иде бит... Аның нәселе өчен ачылган иде. Әмма моның шулай икәнлеген ул әле бик күп еллар үткәч кенә аңлар. Ә хәзергә ул, сабый йокысы белән, төшләр күрә-күрә, изрәп йоклый.

## Алтынчы бүлек

1949 елның 11 июнь көнне, иртән сигез тулып унсигез минут киткәч, Чиләбе өлкәсенең Коншак районында «йолдыз яңгыры», ягъни метеорит ява.

Башта, зәңгәр күкне урталай телеп, җир өстенә зур утлы таш — болид атыла. Җиргә җитәрәк, бу янарташ, утлы чаткылар чәчә-чәчә, берничә кисәккә таркала. Иң зур метеорит Коншак тирәсендәге Чабаккүлгә атылып барып төшә. Ул

шулхәтле зур була ки, аның авырлыгыннан күл өстенә егерме метр биеклектә су баганасы күтәрелә. Соңыннан күпме эзләсәләр дә, күктән төшкән ташны таба алмыйлар — ул төпкә китә. Бар тирә-як күктән яуган вак таш белән тула. Бу күкләрнең әйтерсең лә шул рәвешле тагын бер тапкыр кисәтүе була. Әмма кешеләр бу хәбәрне дә аңламыйлар, җәннәт кебек җирләргә үз башларына атом афәтен алып киләләр.

1948 елның 19 июнендә Иртәштә беренче атом реакторы эшли башлый, ул атом бомбасы өчен плутоний әзерли.

1949 елның язында инде беренче совет атом бомбасы әзер була.

1949 елның 29 августында коточкыч бу үлем коралын инде сынарга әзерләнәләр...

Күктән кешеләргә кисәтү арты кисәтү килә, әмма кешеләр аны аңламыйлар.

Бөек Ватан сугышыннан соң, бөтен ил хәрабәләргә батып, ачлыктан, юклыктан, ятимлектән газап чигеп ятканда, СССРның барлык акыл көче, акчасы, эшче көчләре Чиләбе өлкәсендәге атом төзелешенә ыргытыла. Бу төзелеш илдә иң мөһим һәм иң яшерен эш була, аның белән турыдан-туры Сталин үзе җитәкчелек итә. Кан косып һәм сеңерләре шартлап өзелгәнче көчәнеп, радиация өлкәсендә тәҗрибәсе булмаганлыктан, бу эштә беренче корбаннарны биреп, 1949 елның җәенә Иртәштә беренче совет атом бомбасын ясап өлгерәләр. Бу хакта шунда ук Сталинга хәбәр бирелә. Һәм 1949 елның 29 августында казах далаларында СССРның беренче атом бомбасы сынала. Моның өчен Мәскәүдән Берия үзе очып килеп җитә, атом шәһәреннән Курчатов, Ткаченко һәм башка галим-генераллар җыела.

Бу гаять җитди һәм яшерен эшкә казах далаларында ел буе әзерлек бара. Атом бомбасын сынау урыны итеп татарлар күпләп яшәгән Семипалатинский шәһәреннән 120 чакрым ераклыкта булган буш даланы алалар. Атом-төш коралын урнаштыру өчен утыз метр биеклектәге тимер каланчалар төзелә, бу сынауларны күзәтү өчен җир астында да утыз метр тирәнлектәге базлар казыла. Галимнәр һәм генераллар өчен иң мөһиме — атом бомбасының шартлау нәтиҗәләре булганлыктан, моны өйрәнү өчен җир өстенә махсус шәһәрчек төзелә. Шартлау буласы җирнең үзәгеннән бер чакрым ераклыкта өч катлы таш йортлар үсеп чыга, тимер юл төзелә, анда ягулык тулы цистерналар урнаштырыла. Шулар янәшәсендә генә тимер-бетон күпер салалар. Атом үзәгеннән чакрым ярым ераклыкта исә дизель-генераторлардан эшли торган электростанция дә төзеп куялар, ике чакрымга җиткереп, тимерчыбыклар сузалар.

Ул гына да түгел, төрле урыннарга тимер-бетоннан аэродром мәйданчыклары төзиләр, аларга төрле модельдәге чын самолетлар, танклар, артиллерия, ракета җайланмалары, хәрби корабльләр урнаштыралар, бу тирәне корал белән тутыралар. Болар барысы да атом бомбасының көчен сынау өчен кирәк була. Үзәктән бер чакрым ераклыкта, һәр биш йөз метр саен, ун «Победа» машинасы тезеп куялар. Сынау мәйданы тирәсенә окоплар, җир асты куышлары һәм юллары ясала. Даланы һәм махсус яшеренү урыннарын сарык, дуңгыз, дөя кебек мал-туар, эт һәм күселәр белән тутыралар. Бу җан ияләре дә атом бомбасының, бигрәк тә радиациянең тәэсирен, көчен өйрәнү өчен кирәк була. Соңыннан дүрт аяклы бу мәхлукларны Караболак халкы алыштырыр, чөнки кул астында тере материал булганда, хөкүмәт аны читтән эзләмәс. Атомны алга таба кешеләр өстендә сынауны күздә тотып, полигонга күп итеп азык-төлек тә кертеп тутырырлар, далада өем-өем колбаса, шоколад, эчемлек һәм төрле ризыклар аунап ятар. Галимнәр соңыннан аларда радиация микъдарын билгеләрләр һәм Иртәш тирәсендә дә шушы чамадан чыгып эш итәрләр.

Шулай итеп, 1949 елның 29 августы, иртәнге сәгать җиде…

Япониядәге атом бомбасы шартлауның коточкыч нәтиҗәләрен яхшы белгән совет разведкасы сынау вакытында үзләрен саклау өчен бөтен чараларын күрә. Алар хәтта амбразуралардан күзәтү мөмкинлегеннән дә баш тарталар, киресенчә, шартлау вакытында җир астындагы тимер бункерларына кереп качалар. Өстә бу мәхшәрне кинога төшерергә махсус җайланмалар куела, бу эшләрне гади хәрбиләр башкара. Ә Берия, Курчатов, Ткаченко һәм башка түрәләр, шартлау вакытында стена буеннан читкә китеп, уртага өеләләр. Башкалар өчен үлем әзерләсәләр дә, аларның үзләренә җан бик кадерле була.

Менә көтелгән вакыт килеп җитә. Хәрбиләр секундларны саныйлар. Менә җир селкенеп, сикереп куя һәм коточкыч көчле шартлау тавышы яңгырый. Өстә нидер дөберди, чатырдый, уһылдый, улый-үкерә башлый. Аннан барысы да кинәт тынып кала. Бераз вакыт үткәч, махсус җайланмалар киеп, барысы да өскә чыга. Еракта, атом полигоны булган урында, күккә багана кебек утлы гөмбә күтәрелгәнне күреп, алар барысын да аңлый. Димәк, сынау уңышлы үткән! Күккә, нәкъ Хиросима һәм Нагасакидагы кебек, кызгылт-кара атом гөмбәсе күтәрелә. Тирә-якта җансыз табигать җәйрәп ята. Алар шушы нәтиҗәгә ирешү өчен ничә еллар баш күтәрми эшләде бит — таулар актардылар, урманнар кистеләр, сазлыкларны киптерделәр, юк җирдә шәһәрләр салдылар, җир астында заводлар төзеделәр, ураннан плутонийны ае-

рып алып, атом бомбасы ясарга өйрәнделәр! Һәм ясадылар! Аларның күз алдында шуның нәтиҗәсе! СССР тагы Американың борынына сукты, аның кулында хәзер атом бомбасы һәм ул бөтен капиталистик дөньяны тезләндерәчәк! Дөньяга алар хуҗа булачак! Урыс генераллары бу мизгелдә әнә шулар турында уйлыйлар иде.

Генераллар яңадан бункерга кереп, кочаклашып, бер-берләрен котладылар, шатлыктан аларның күзләренә хәтта яшь килде. Берия шунда ук рациядән Сталинга чыкты, аңа сынауның уңышлы үтүен хәбәр итте. Икенче көнне бу хәбәр бөтен дөньяга таралды. Дөнья атом-төш коралы чорына керде. Илләр һәм дәүләтләр арасында «салкын сугыш» чоры башланды. Атом коралына ияреп, радиация килде, радиация яман шеш үләтен — ракны тудырды. Илләрдә һәм җирләрдә үз халыкларына каршы күзгә күренмәгән үләт — радиация сугышы башланды.

Икенче көнне генераллар һәм атомчы галимнәр, махсус киемнәр киеп, сынау булган урынны карарга киттеләр. Алар күргән күренеш котны алырлык иде. Атом шартлавы көченнән өч катлы таш йортлар шырпы тартмасы кебек ишелеп төшкән, «Победа» машиналарының тимеренә хәтле янып беткән. Ялкынлы атом дулкыны тимер юлларны һәм бетон күперләрне бау кебек бәйләп, утыз метр читкә алып бәргән. Вагоннар һәм төрле җайланмалар, изелеп-сытылып, дала буйлап сибеп ташланган. Танклар әйләнеп капланган, пушкалар янган тимер өеменә әйләнгән. Алар янында, аякларын сузып, этләр, сарыклар аунап ята, аларның эчәкләре актарылып чыккан, күзләре агып ята. Үлгән дөяләрнең өсләреннән тиреләре кубып төшкән. Бар тирә-як үле һәм үлек белән тулган иде. Бу төрки далаларда егерме мең тонна тротил көченә ия булган беренче совет атом бомбасы шартлатылган иде. Һәм бу үлем коралы адәм балаларын юк итү өчен эшләнелгән иде.

СССР (Сталин һәм Берия командасы), Американы узып китәргә омтылып, котырып корал җитештерергә тотынды. 1950 елның мартында Иртәш күле буендагы җир асты заводларында икенче атом реакторы эшкә җибәрелде. 1951 елның апрелендә — өченче реактор, шул елның октябрендә — дүртенче, декабрь аенда бишенче атом казаны эшли башлады. Караболак, Мәшәләк, Теча-Дениз, Синара елгаларын, Иртәш, Әбиташ, Кояш, Карачай, Кызылташ, Олыагач күлләрен, урман-суларны, йөзләгән татар авылларын атом сөреме каплап китте, тирә-якка күзгә күренмәс үлем — радиация тарала башлады.

Атом реакторлары атлаган саен ватылды, җиһазлар шартлады, куркыныч атом калдыклары суга, һавага таралды, туф-

ракка сеңде. Атом цехларында эшләүчеләр, зур дәрәҗәдә радиация алып, мизгел эчендә сукырайдылар, каннары агуланды, үпкәләре янып чыкты, тереләй чери башладылар. Кешеләр арасында моңа кадәр күренмәгән яңа авыру — яман шеш килеп чыкты, ул халыкны «чалгы белән кыра башлады».

Бу зәхмәтләр җир астына яшерелгән тимерчыбыклы шәһәрләрне дә бәреп чыгып, тирә-юньгә, татар авылларына таралды.

Гөлҗиһаннар авылы бу үлем юлының нәкъ өстендә ята иде.

## Җиденче бүлек

1957 елның 29 сентябре кояшлы, җылы якшәмбе көне иде...

Караболак авылында якшәмбене «урыс атнасы» дип йөртәләр, чөнки күрше урыс авылында бу көнне берни эшләмиләр, бәйрәм итәләр. Менә бүген дә Урыс Караболагы авылы кырына эшкә Татар Караболагы халкын җыеп алып киттеләр, ял көне булуга карамастан, хәтта мәктәп балаларын да кырга чыгардылар. Менә хәзер бала-чагасы, яше-карты — барысы да колхоз кырында бәрәңге, чөгендер, кишер, кәбестә алалар. Караболак татарларын эш белән куркытып булмый, эш үзе алардан курка, тагы берничә көннән бу кырларның ялт итеп каласын бөтенесе дә яхшы белә.

Унбер яшьлек Гөлҗиһан да халык арасында кайнаша. Ул үзенең гаять терелеге, үткенлеге, янып торган сирәк матурлыгы белән барысыннан да аерылып тора. Гөлҗиһанга барысы да кызык, ул барысын да булдыра, кайда куйсаң да эшен ялт итеп эшләп ташлый, шаянлыгы, чаялыгы белән беркемгә дә тынгылык бирми. Аның ике бите һәрвакыт ут булып янып тора, зур яшькелт күзләре тирә-якка нур чәчә, кырны яңгыратып көлгәндә, аның кыңгырау тавышыннан танып, әти-әнисе дә борылып карый. Аны бөтен кеше ярата — өйдә дә, авылда да, мәктәптә дә, кырда да... Яратуларын Гөлҗиһан үзе дә белә, шуңа күрә бераз үсенеп тә китә, иркәләнеп, арттырыбрак та җибәрә. Әнә хәзер дә әтисенең атлы арбасына менеп баскан да үз белдеге белән кырның бер башыннан икенчесенә су таратып йөри. Бригадир Нәбиулла кызы булгангамы, Гөлҗиһан үзе бик сөйкемле бала булганы өченме, әллә, чынлап та, бик эчәселәре килгәнгәме аны, кем янына килсә дә, шатланып каршы алалар, рәхмәт әйтеп озаталар. Инде картаеп килгән туры айгыр да Гөлҗиһанга берсүзсез буйсына, ул дилбегәне кайсы якка тартса, тыныч кына шунда борыла. Заманында ирләр дә тыңлата алмаган туры айгырны Гөлҗиһан песи баласы кебек кенә уйнатып йөртә.

Тузанлы бәрәңге буразнасына кереп баткан классташлары аннан бераз көнләшәләр дә, әмма ачулары килми, чөнки Гөлҗиһанга барыбер ачуланып булмый. Аны бары тик яратып кына була. Ул алар арасында иң башлы бала, бишенче класска җитеп, әле аның хәтта бер тапкыр да дүртле билгесе алганы юк, гел бишле. Ул класста иң матур кыз, юк, мәктәптә, хәтта Караболакта иң матур кыз, бөтен кеше шулай ди. Ул үз яшенә караганда күпкә гәүдәле, сылу, күз явын алырлык бәхетле бала. Аның белән дуслашырга теләүчеләр бик күп, әмма ул барысына да тигез карый, тик класстагы иң оялчан, сүзсез кыз Рәшидәне генә аеруча якын итә, кызгана. Чөнки Рәшидә бик кыюсыз, яшереп кенә шигырьләр яза, шуңамы, малайлар аннан көлә, рәнҗетә, ә Гөлҗиһан аны ярсып яклый. Хәзер дә әнә, атын-арбасын онытып, Рәшидәне бәрәңге арасына төртеп еккан малайлар белән пыр тузып сугышып ята. Малайлар, командир кызга буйсынып, берәм-берәм качу ягын карыйлар.

Ә Гөлҗиһанның бүген тизрәк өйгә кайтасы килә. Чөнки бүген аларда кунак бар! Аларга улы белән бергә Якуп абыйлар килде. Әтисенең әйтүе буенча, ун ел элек аларны авылдан Урал аръягына сөргән булганнар, хәзер менә нигез карарга кайтканнар. Гөлҗиһанны бигрәк тә аның Фәргать исемле улы гаҗәпләндерде — ул бөтенләй Караболак малайларына охшамаган иде. Ул инде малай да түгел — җиткән егет кебек, үзе гәүдәле, үзе әллә нинди матур, сөйкемле. Үзе гел Гөлҗиһанга карап утыра. «Хәтерлисеңме, мин сине бәләкәй вакытта күтәреп йөрткән идем бит?» — ди. Кызык малай инде бу Фәргать, ул вакытны каян хәтерләсен инде Гөлҗиһан? Ул үзенең тормышын күк капусы ачылган көннән генә хәтерли. Бөтен Караболакны яктырткан зәңгәр нурны хәтерли, идән ярыгындагы сыңар мәрҗән хәтеренә уелып калган. Әбисенең кулындагы чынаяк калтыравын, бабасының сузып-сузып намаз укуын бүген дә ишетә кебек. «Күк кабагы ачылды, кызым, теләк телә...» Һәм үзенең теләгән бик яхшы хәтерли Гөлҗиһан, ул әти-әнисенең, әби-бабасының, Караболакның гел-гел булуын, мәңге булуын теләде. Ул вакытта Гөлҗиһан Фәргать дигән күрше малаен белми дә иде әле.

Аннан Гөлҗиһан бик сәер төш күрүен хәтерли — ул Караболак өстеннән, Иртәш буйларыннан очып йөри икән. Аста зур-зур таш йортлар, бик күп кешеләр һәм шулар арасында Гөлҗиһан үзе дә. Әмма ул инде зур үскән, әнисе кебек булган. Аның янында балалары да бар икән һәм ниндидер бер чит ир-ат. Тукта, аның йөзен Гөлҗиһан инде кайдадыр күргән иде бит! Бәй, бу теге, Урал аръягыннан кунакка килгән күрше егете Фәргать бит! Тик Гөлҗиһанның сабый чак төшендә ул нигәдер кап-кара күзлектән иде.

Шушылар исенә төшкәч, Гөлҗиһан арбасыннан егылып төшә язды. Нишләп ул вакытта төшенә керде икән аның ул күрше абые? Бәлки, бәләкәй чагында кулларына күтәреп йөргән өчендер? Әнисенең сөйләве буенча, ул бит Гөлҗиһанны үз туганын караган кебек караган, алардан чыгып та тормаган. Менә шуңа күрә төшенә дә аның белән янәшә кергәндер. Боларны уйлагач, Гөлҗиһанның болай да мәрҗән кебек битләре ут булып яна башлады. Ул нигәдер оялып китте, аның бу халәтен кемдер читтән күзәтеп торадыр төсле тоелды. Шул уңайсыз хәленнән котылырга теләгәндәй, ул арбага аягүрә торып басты, дилбегәсен баш очында уйнатып, туры айгырны куа башлады. Карт атка да дәрт кергәндәй булды, ул буш кыр буйлап тузан туздырып чабып китте. Гөлҗиһан салкын су бидонын тез арасына кысып тотты, су, чайпалып, аның тузанлы аякларын чылатты. Көзге йомшак җылы җил аның уттай янган битләреннән сыйпап үтте, авыл баласының тыгыз тәнен, ихлас җанын иркәләде. Гөлҗиһанга бу мизгелләрдә бик-бик рәхәт иде, бу кырлар, бу күлләр, бу авыл, бу дөнья аныкы, бары тик аныкы гына иде.

Әнә кыр башында, һаман нидер үлчәп, һаман нидер оештырып, әтисе йөри. Гөлҗиһан янына килмәсә дә, ул күз кырые белән генә аны гел күзәтә, бәла-казадан саклый кебек. Әнә хатын-кызлар арасында аның әнисе бәрәңге чүпләп йөри, ул да бу якка борылып, Гөлҗиһанга карап-карап ала. Ул да күңеле белән Гөлҗиһанны бәла-казалардан саклый. Әнә авылның әүлиясы Таһирҗан бабай, Караболакта Гөлҗиһанны иң нык яратучы кеше. Ул Ярулла карттайның энесе, авылның иң абруйлы кешесе, халыкча итеп әйткәндә — изгесе. Ул үзе тракторда эшли, әмма гел намазын укый, хәтта кырда да вакыт таба, Гөлҗиһанның үзенең күргәне бар. Моннан берничә ел элек Таһирҗан бабай мәрткә киткән булган. Бу хәл зиратта җеназа укыганнан соң булган, Караболак гадәте буенча кабер саклап калган Таһирҗан бабайны икенче көнне чак табып алалар. Ул аңсыз яткан була, аны үлгән дип беләләр, күмәргә хәзерләнәләр, ә ул мәрткә генә киткән икән. Аңына килгәч, Таһирҗан бабай кеше белмәгән телдә сөйли башлый, картларның әйтүенчә, бу гарәп теле була. Шуннан Таһирҗан бабай Коръән ятлап уяна: «Миңа мәрткә киткәндә җәннәт белән җәһәннәмне күрсәттеләр, тик барысын да сөйләмәскә куштылар», — ди. Шуңа күрә аны авылда әүлия дип йөртәләр. Таһирҗан бабай авылда мулла да булып йөри, гаетләр укыта, совет власте аның белән бернишли алмый, ул: «Миңа тегендә шулай куштылар», — дип кенә җавап бирә. Таһирҗан бабайны тагы әллә нәрсәләр белә, диләр, тик ул үзе бу турыда сөйләми. «Чиктән узарга ярамый», — ди. Ә Гөлҗиһанны бик ярата ул, аңа бик күп нәрсәләр сөйли,

укытучылардан яшереп, догаларга хәтле өйрәтә. «Синең хәтерең бик яхшы, кызым, өйрән, болар әле барысы да кирәк булачак сиңа», — ди. Гөлҗиһан хәтта намаз сүрәләренә хәтле өйрәнеп килә инде, Таһирҗан бабай аны Коръән укырга да өйрәтергә булды әле.

Әмма Гөлҗиһан өчен иң кызыгы — Таһирҗан бабай сөйләгән Караболак тарихы булды. Мәктәптә аларга бөтенләй башка төрле аңлатканнар иде. Дөресрәге, аларга мәктәптә татарлар турында да, Караболак тарихы турында да берни сөйләмиләр, гел революция, Ватан сугышы, СССР тарихын гына сөйлиләр. Гөлҗиһан аларын да бик яхшы белә, әмма аның Караболак турында, татарлар турында күбрәк беләсе килә бит! Ә тарих китапларында бу хакта берни язылмаган. Укытучылар да белми, сөйләми. Ә Таһирҗан бабасы әллә нәрсәләр белә булып чыкты, болар хакында Гөлҗиһанның беркемнән дә ишеткәне булмаган иде, хәтта әтисеннән дә.

Быел җәй Таһирҗан бабай аны Биташ күле буена алып барды. Олылар аны Аллакүл ди, балалар Әбиташ яки Биташ дип кенә җибәрә. Гөлҗиһанның монда элек тә булганы бар иде инде, алар монда балалар белән уйнарга бик яраталар. Тау куышының иң теге башына кереп китәләр дә беркем таба алмаслык булып качалар. Аннан тау башыннан күлгә сикерәләр, куллары белән су төбендәге салкын ләмгә хәтле төшеп җитәләр. Су өстенә чыккач, учларындагы ул ләм зәңгәргә әйләнә, кулларын җылытып тора башлый. Яр буенда да шундый ук зәңгәр ләм тулып ята, авыл халкы аны, өшкереп, тәненә сөртә, шуның белән дәвалана. Әле тау куышыннан салкын чишмә агып чыга, аның суы тешләрне камаштыра, әмма туңдырмый. Караболак халкы аны да шифалы ди, картлар өшкереп эчәләр. Таһирҗан бабай биредән гел шуларны ташый, кайвакытта Гөлҗиһан да аңа ияреп бара.

— Бабай, нигә бу күлне Аллакүл дип тә, Әбиташ дип тә атыйлар, Биташ бит инде ул? — дип сорады Гөлҗиһан бу юлы Таһирҗан бабасыннан.

— Аның сере бик еракларда инде, кызым, Нух пәйгамбәр заманнарына ук барып тоташа, — дип башлады сүзен Таһирҗан карт. — Әнә мәгарә каршында зур ташны күрәсеңме? Туфаннан соң Алып бабай шунда басып намаз укыган дип сөйлиләр иде безгә.

— Ә безгә укытучы «Туфан — әкият ул» диде.

— Дөньяны су басу турында Коръәндә бар, кызым, — диде Таһирҗан карт, сабыр гына. — Ә Коръән әкият була алмый. Дөньяны су басканнан соң, Нух пәйгамбәрнең нәселе генә исән кала. Безнең бабайларның сөйләүләре буенча, алар Урал тауларында туфан үткәнне көтәләр. Аннан аска төшәләр. Безнең авыл ул урыннардан ерак түгел, әнә Урал

таулары күренеп кенә тора бит. Алып бабай менә шул ташка басып, исән калганы өчен Аллага рәхмәт әйткән, намаз укыган, диләр, шуңа күрә күлнең исеме дә башта Аллакүл булган. Алып бабай шушында яшәп калган, авылга нигез салган, аның кабере дә әнә моннан биек булып күренеп тора, сезгә аны курган дип өйрәтәләр инде.

— Ә нигә соңыннан Әбиташ дип атала башлаган соң, алайса?

— Кешеләр әкренләп Алланы онытканнар, кызым, менә хәзерге кебек. Күл тирәли унике сын ясап куеп, шулар ярдәм итә дип белеп, аларга табына башлаганнар.

— Хәзер Ленин бабайга һәйкәл куйган кебекме? — дип сорады Гөлҗиһан, шунда ук чагыштырып карап.

Таһирҗан карт ерак оныгының бик зиһенле, хикмәтле бала икәнлеген белә иде, бу чагыштыруны бик дөрес дип тапты. Әмма бу баланың бит әле шушы дөньяда, шушы кешеләр арасында яшисе бар, һәр уйлаганны ачып салмаска да өйрәнергә тиеш ул.

— Шулай, кызым, — диде ул. — Әмма бу хакта син бүтән кешегә әйтмә, яме!.. Кайда калдым әле мин?

— Нигә Әбиташ, аннан Биташ булган, шуны сөйлисе идең, бабай!

— Әйе... Монысын халык сөйли инде. «Әби» дә, «Би» дә бер үк тамырдан чыккан — каенана дигәнне аңлатырга мөмкин... Бер йомшак килен белән усал каенана килешә алмаганнар да, каенана килененә «ташка әйләнсен» дип каргаган, имеш. Һәм үзе шул минутта ташка әйләнгән, ә килененә бернәрсә булмаган. Кешене каргарга ярамый, кызым, ул каргыш үзеңә төшәргә мөмкин икән. Менә бу таш сыннар шул хакта да сөйлиләр. Бу күлләр турында халык арасында элек башка төрле сүзләр дә йөри иде. Имеш, туфан таралганнан соң Уралтаудан төшкән Алып кешеләр бу куе урманлы җирләрдә бер-берләрен югалтканнар. Берсе — Иртәшкә, икенчесе Әбиташка килеп чыкканнар, ягъни бу күлләрне үз исемнәре белән атап йөртә башлаганнар...

— Алар бер-берләрен таба алганнармы соң?

— Юк, кызым, алар бер-берләрен таба алмаганнар. Аллаһы Тәгаләдән хәбәр килгән, шушы күлләрнең сулары яңадан бергә кушылгач кына сез күрешә аласыз, дип. Бу — заман ахырында буласы икән. Һәм аңа инде озак калмаган...

Гөлҗиһанга ул вакытта бик куркыныч булып киткән иде. Чөнки Таһирҗан бабай да бик шомлы сөйли, күл буендагы җимерек сыннар да аңа бөтенләй башкача күренә башладылар. Теге күрешә алмаган Алып кешеләр дә бик кызганыч...

— Алар күрешә алмагач, монда кемнәр яшәгән соң, бабай? — дип сорады ул, мәсьәләнең төбенә төшәсе килеп.

— Әй, кызым, кемнәр генә яшәмәгән бу тирәләрдә, — дип җавап бирде Таһирҗан карт, бер ерактагы Урал тауларына, бер Караболак ягына карап. — Монда иң борынгы кешеләр, Алып бабалар, ханнар-патшалар яшәгән, кызым. Мәрткә киткәндә миңа аларның барысын да күрсәттеләр. Мин Караболакны уч төбемдәге кебек күрдем — үткәнен дә, киләчәген дә...

— Таһирҗан бабай, миңа шуларны сөйлә әле! Сөйлә, сөйлә! — дип, аңа ялына башлады Гөлҗиһан, сулышына кабынып.

— Боларны сиңа сөйләргә бераз иртәрәк әле, кызым, — диде Таһирҗан карт, Гөлҗиһанның шомырт чәчләреннән сыйпап. — Бераз гына үс әле, сөйләрмен, иншаллаһ!

Гөлҗиһанның авызын турсайтып, үпкәләп утыруын күреп, Таһирҗан карт аны кызганды, ахры:

— Менә мин сиңа хәзер шунда ишетеп кайткан бер шигырьне сөйлим алайса, — диде ул. — Бәлки, бу шигырь дә түгелдер, әмма анда барысы менә шул рәвешле — шигырь белән сөйли. Йә, тыңла алайса...

Әй, милләтнең сылу балалары,
Дөнья тетрәткән Хан бабалары!
Ханыңны, барча гаскәреңне
Дошман узып китте...
Куәтле, шәүкәтле чакларың
кайларга китте?
Җыелыгыз, түгелгән канлы күз яшьләр,
Атлагыз алга! Күрсен көндәшләр...
Чәч гайрәт! Баһадир бәһале Җан Син!
Фикерең — бер мәмләкәт,
син аңа җансың.
Гайрәтле бер милләт җитәкчесе бит без,
Ялкынлы милләтнең аркасы бит без!
Яшәде дөньяда баһадир бабаң,
Диде ул, якты тормышта яшәсен балам!
Яшә син дөньяда, ал Коръән кулга,
Шул — тугры юл,
карама уңга да сулга!
Дөньяны гизеп йөр, бар алга таба!
Гизде бит дөньяны һәм Чыңгыз бабаң.
Арма син, Алып Хан нәселе, дошманнан калма!
Алга бас, татар, алга бас, алга!

Гөлҗиһан бу шигырьне шунда ук ятлап алды, ул аңа шундый ошаган иде. Ул аны, дәфтәр битенә күчереп язып, Казанда һәм Уфада чыга торган татарча газеталарга да җибәреп карады, әмма алардан «бу әле шигырь булып бетмәгән» дигән хәбәр генә алды. Һәм быел беренче сентябрь көнне, бөтен мәктәп тантаналы рәткә тезелгәч, Гөлҗиһан, Караболакны яңгыратып, шушы шигырьне сөйләп җибәрде. Ул партиягә, совет властена рәхмәт укыган шигырь сөйләргә тиеш иде, Гөлҗиһан тотты да Таһирҗан бабасының шигырен сөй-

ләде. Әллә нәрсә башланды мәктәп ишегалдында! Укытучыларны умарта корты чактымыни — гөж киләләр, арлыбирле чабулыйлар, Гөлҗиһанны ничек туктатырга белмиләр. Туктатырсың Алып Хан Нәбиулла кызын бер сөйли башлагач! Әле ярый районнан килгән вәкил татарча аңламый икән, шулай йолып калдылар Гөлҗиһанның Коръән турында, Хан бабалар турындагы шигырен. Мондый саташуны башка бер җирдә дә укымаска куштылар, хәтта әти-әнисен дә кисәтеп маташтылар.

Шушылар исенә төшкәч, Гөлҗиһанның бөтен Караболак кырын яңгыратып, тагы шул шигырьне укыйсы килеп китте. Бик нык ошады ул аңа, бөтен күзәнәкләрен уятты, үзен уятты. Бу шигырь аңа үзе турында язылган кебек тоелды, чөнки алар да бит Алып Ханнар нәселе кушаматын йөртәләр, фамилияләре дә — Хановлар... Бу шигырьне әле яшь вакытта ук Таһирҗан бабай үзе язган, дип тә әйтәләр, чөнки революциягә хәтле ул бераз Казанда укып йөргән бит.

Гөлҗиһан, арбасына басып, күзләре белән Таһирҗан бабасын эзли башлады. Әнә бит ул, ирләр белән бергә, бәрәңге капчыкларын арбаларга төйи. Шушы шигырьне сөйли-сөйли, Гөлҗиһан хәзер аның янына барып җитәчәк, инде кайтыр вакыт та якынлаша, алар аннан авылга бергә кайтып китәчәкләр. Ә өйдә аларны кунаклар көтә, әбисе бүген тавык суйгандыр, канатын, һичшиксез, Гөлҗиһанга бирәчәкләр. Ул бит өйдән очып китәсе кыз бала икән, әбисе гел шулай ди. Ә кайда очар Гөлҗиһан — ул аны үзе дә белми, хәзергә аның Караболактан бер җиргә дә китәсе килми. Ул хәзергә менә Караболак кыры буйлап оча, кояшка, җилгә таба оча!

Әй, милләтнең сылу балалары!
Дөнья тетрәткән Хан бабалары!
Арма син, Алып Хан нәселе, дошманнан калма!
Алга бас, татар, алга бас, алга!

Башындагы ак яулыгын байрак итеп кулына тотып, Гөлҗиһан Караболак кыры буйлап оча. Аңа таба зәңгәр күк оча, кояш үзе оча, кешеләр оча. Кинәт шунда әллә нәрсә була. Туры айгыр очып барган җиреннән чүгеп куя да, дөньяны яңгыраткан гөрселдәү авазыннан шашып, кыр буйлап чабып китә. Су бидоны җиргә тәгәрәп барып төшә, аның артыннан Гөлҗиһан үзе дә җиргә тәгәри. Шул вакытта Иртәш ягында тагы көчле гөрселдәү ишетелә, аяк астындагы җир селкенеп, сикереп куя. Берни аңламыйча калган Гөлҗиһан аягына басарга тырыша, әмма әллә җирнең селкенүеннән, әллә башы әйләнүдән, тезләренә генә калка ала. Ул аяк астындагы җирнең гүләп улаганын ишетә. Гөлҗиһан гаҗәпләнеп тирә-ягына карый — башкалар да кайсы чүгәләгән, кайсы

тезләнгән, барысы да Иртәш ягындагы күккә төбәлгән. Ә анда — ике кояш. Кан кебек кызыл кояш. Юк, бу — кояш түгел бит, бу — гөмбә кебек утлы багана, сураеп, Иртәш өстенә күтәрелә. Гөлҗиһан Караболак өстендә, Уралтау буйларында көпә-көндез аҗаган уйнаганын күрде, җансыз зәңгәр нурлар бөтен тирә-якка шомлы хәбәр тараталар иде...

Шул вакыт салкын зәһәр җил исә башлады, ул Иртәш өстендәге утлы баганаgreat йолыккалап, Караболак ягына таба куды. Авыл өстенә, кырда эшләгән балалар һәм олылар өстенә үлем болыты килгәнлеген әле беркем дә белми иде. Ул арада күк йөзе караңгыланып китте, Иртәш ягыннан искән җил борынга сасы йомырка исен китереп бәрде. Кем яулык, кем күлмәк итәге белән битен-йөзен каплый башлады, кайбер балалар, бу искә чыдый алмыйча, укшып ук җибәрделәр.

Гөлҗиһанның да күңеле болгана башлады, күз аллары караңгыланып китте, башы чатнап-чатнап авыртырга тотынды. Олыларның да рәте юк иде, ахры, алар башлаган эшне тәмамларга ашыктылар. Капчыкларга тутырган бәрәңгеләрне авылга озаттылар, көшелдәгеләренең өстен капладылар да кичкә таба кайтырга кузгалдылар. Барысының да телендә Иртәш ягында ишетелгән көчле шартлау һәм күккә күтәрелгән утлы багана иде. Ул арада кыр өстенә әллә нинди сәер томан таралды, ул авыраеп, авыл һәм агачлар өстенә, елга-суларга төшеп утырды, кешеләргә кагылып үтте. Кешеләр моның үлем томаны икәнлеген белмиләр иде әле...

Гөлҗиһан исә бүген авылга әтисенең атында кайтты. Әле генә ут кебек очынып йөргән баланың кинәт кенә сүрелеп, боегып калуын күргәч, әтисе үзе килеп, аны янына утыртты. Авырлы әнисенең дә кәефе юк иде, ул гел алъяпкычына капланып укшыды, йөзе-бите тимгел-тимгел булып чыкты. Алай да аның бөтен игътибары кызы Гөлҗиһанда иде, ул аны алдына яткырып, гел башын тотып кайтты. Ә Гөлҗиһанның башы, дөньяда әле беркайчан булмаганча, чатнап-чатнап авырта иде. Юк, аның башы гына түгел, колаклары да шаулап авырта, күзләре атылып чыгарлык булып сызлый. Әмма ул еларга ояла, авыртуга чыдый алмый, әнисенең алъяпкычын тешләре белән кыса, уртларыннан хәтта кан чәчрәп чыга. Аннан ул әллә йокыга китә, әллә аңын җуя. Шул хәлендә, саташа-саташа, авылга кайтып җитә. Иртән өйдән шаян тай кебек чыгып чапкан онытыгының аңсыз хәлдә әтисе кулында кайтып керүен күреп, Нурҗамал карчык өнсез кала, баланы тизрәк үзләренә алып кереп сала. Гөлҗиһан өчен яшәү белән үлем арасында көрәш башлана.

Бала берничә көн тоташ ут эчендә ята.

Аның авыз-борыныннан, хәтта колакларыннан шаулап кан

китә, башындагы чәчләре коела, туктаусыз эче китә. Авылда врач юк, булса да, ул барысын да карап өлгермәс иде, чөнки һәр йортта диярлек шушы хәл. Бигрәк тә балалар интегә, хәтта күзләре сукырайганнар да бар, барысының да авыз-борыныннан кан китә, чәчләре коела. Кайберләре, баш авыртуга чыдый алмыйча, идәндә аунап-тәгәрәп йөриләр. Гомерендә мондый хәлне күрмәгән авыл халкы курка калды, олылар арасында да баш авыртулар, канлы эч китүләр күбәйде. Һәркем үзе белгәнчә дәвалана, кем, өшкереп, Биташ чишмәсе суын эчә, кем мунча ягып керә, кем, бал белән, кем төрле үләннәр белән сихәт табарга тырыша... Ашыгыч рәвештә Коншак, Чиләбе больницаларына барып ятучылар, кинәт кенә үлеп китүчеләр дә күренә башлады. Караболак халкы авыл белән чирләп китүнең сәбәпләрен белми, ә белгән кешеләр дәшми иде. Чөнки болар барысы да атом белән бәйләнгән, дәүләт сере булып тора иде... Әмма Караболак өчен бу әле зур афәтнең башы гына, бу атом аждаһасы авыл халкын тәмам кырып бетермичә туктамаячак иде. Тик Караболак халкы бу турыда да берни белми иде...

Таһирҗан бабасының догалары, карттай-нәнәенең теләкләре, инәй-атаеның өзелеп яратуы Гөлҗиһанны бу юлы үлем тырнагыннан алып кала. Ул үзенә билгеләнгән гомерне яшәп бетерергә, атом казаннарында кайнап та исән калырга, атом аждаһасына каршы берьялгызы тиңсез көрәшкә күтәрелергә, кешеләрне бу бәладән кисәтеп өлгерергә тиеш була...

## Сигезенче бүлек

Ул көнне Иртәш буйларында да гаҗәеп матур көзге көн иде.

Сталин үлгәч, атом бомбасы ясый торган шәһәр дә бераз иркенәеп, төрмә чикләреннән чыгып яши башлаган иде. Дөрес, ул әле һаман ябык зона дип йөртелә, аны һаман коралды сакчылар саклый, дәүләт серен ачкан өчен һаман да үлем җәзасы — трибунал көтә. Әмма хәзер шәһәрдә хакимият бар, шәһәрнең 1954 елда хөкүмәт биргән чын исеме бар, аны хәзер рәсми кәгазьләрдә Озерский дип йөртәләр. Әмма халык өчен ул һаман — Сороковка, бу — почта бүлегенең адресы, һәм шәһәргә хатлар һаман шулай языла. Сталин үлгәч, атом атаманы Берия атып үтерелгәч, биредәге Ткаченколар да койрыкларын бераз кыстылар, шәһәр бугазындагы тимер кулларын ычкындыра төштеләр. 1954 елда Озерский-Иртәштә беренче тапкыр сайлаулар булып үтте, элек шул ук Ткаченколар кеше санын ачмас өчен, атом шәһәрендә сайлаулар да уздырмыйлар иде. Нәрсә анда сайлаулар — бире-

дә хәтта бәйрәм демонстрацияләре уздыру да тыелган иде, имеш, дошман, Америка очучылары, күктән карап, бирелә ничә кеше яшәгәнен белә һәм аларның нәрсә ясаганнарын чамалый! Ә биредә атом бомбасы ясап яталар...

Һәм Ткаченконың «режимная служба»сы, дәүләт серен саклау өчен, иң кыргый алымнарга хәтле барып җитә. Биредә бөтен нәрсә, бигрәк тә химик элементлар, серле шифр белән генә йөртелә, әйтик, уран — «А-9», водород — «17» һәм шундый яшерен билгеләр... Бөтен эш кәгазьләрендә плутонийны — «продукт», реакторны — «аппарат», ә радиацияне — «грязь», ягъни пычрак дип атыйлар. Хезмәткәрләргә болар хакында бер-берләре белән фикер алышмаска кушыла, алар хәтта бер-берләренең эш бүлмәләренә дә керергә тиеш булмыйлар. Плутоний ясый торган цехтан чыкканда, Ткаченко таләбе буенча кешеләрне шәп-шәрә калдырып чишендерәләр, чәч араларын җентекләп капшыйлар, хатын-кызларның толымнарын сүттерәләр, колак эчләрен актаралар, бармак араларын тикшерәләр. Дәүләт сере булган плутонийны алып чыгулары мөмкин бит! Бу цехларга бары тик җир асты юлы белән генә үтеп була, атом аждаһасы дистәләгән чакрымнарга, җир астына җәелеп яткан. Ә өстә — меңьеллык татар авыллары, зәңгәр сулы күлләр, шифалы чишмәләр, чәчәкле болыннар. Алып Ханнар нәселе, пәйгамбәрләр, әүлиялар токымы...

Сталин үлгәч, атом шәһәре бераз җиңел сулап куя. Иң мөһиме — кешеләргә бу тимер читлектән тышка чыгарга рөхсәт ителә. Халык дәваланырга, ялларга, туганнарын күмәргә шәһәрдән читкә чыгарга рөхсәт ала, ә читләргә монда керү барыбер тыелган килеш кала. Шәһәрдә кинотеатрлар, больницалар, мәктәпләр ачыла, зур-зур таш йортлар үсеп чыга. 1957 елның 29 сентябренә биредә инде утыз өч мең кеше яши. Атом шәһәрендә шулай ук иң пычрак, радиацияле урыннарда тоткыннар эшләгәнлеге һәм хәрби полклар торганлыгы да билгеле. Шәһәр үзенең зур фаҗигасенә менә шундый хәлдә килеп керә. Ял көн булганлыктан, кем — йорт тирәсендә, кем күл буенда була, күпләр «Химик» стадионындагы футбол ярышын карарга китәләр. Халык ялда булса да, атом реакторлары бертуктамый эшләп тора, атом комбинаты, алны-ялны белмичә, үлем коралы җитештерә. Әмма чит илләрдәге дошманнар өчен әзерләнгән үлем СССРның үз халкына каршы юнәлә — 1957 елның 29 сентябрендә Иртәш күле буйларын атом шартлавы тетрәтә. Соңыннан билгеле булганча, бу шартлау Чернобыльнекенә караганда 200 тапкыр көчлерәк була һәм дөньяга 200 миллион кюри атом калдыклары ыргытыла, көчле радиация тарала. Әмма бу хакта халыкка бернәрсә дә әйтмиләр, Иртәш фаҗигасенең ачылуы өчен әле тагы кырык ел вакыт кирәк була, бу вакытта инде

миллионлаган кеше атом нурланышы алган, меңләгән кеше көчле радиациядән, рактан үлеп беткән була.

Әйе, кояшлы матур көзге көн була ул 1957 елның 29 сентябре...

Көндезге дүрт тулып бишенчеләрдә кинәт кенә бөтен дөньяны бик көчле шартлау авазы тетрәтә. Шартлау атом реакторлары ягыннан ишетелә һәм шунда ук күккә утлы-ялкынлы төтен баганасы күтәрелә. Күк йөзе кинәт кенә караңгылана, атомчылар шәһәре көпә-көндез дөм караңгылыкта кала. Күңелләргә шом салып, шәһәр өстендә атом аҗдаганы уйный башлый. Моңа караган кешеләр шунда ук сукыраеп калалар.

Бу гайре табигый хәлдән кошлар сайрауларыннан туктап кала, этләр, киресенчә, караңгы күккә карап улый башлыйлар. Бернәрсә аңламаган, кая барып бәрелергә белмәгән кешеләр өстенә кисәк-кисәк радиоактив калдыклар яварга тотына. Алар өстенә үлем яңгыры ява, әмма моның шулай икәнлеген әле күпләр белми.

Шартлау тавышы шәһәрдәге бөтен тәрәзәләрне коеп төшерә. Шәһәр өстенә таралып барган куе соры атом болытыннан кешеләр кая качарга белмиләр. Моның нәрсә белән бетәсен бераз чамалаганнар тизрәк йортларына кереп бикләнәләр, ватык тәрәзәләрен томалыйлар, базларга төшеп качалар. Әмма атом тузаны аларны аннан да эзләп таба, үлем элмәге булып, тәннәренә, бугазларына утыра, каннарына үтеп керә, аларга әҗәл тамгасын салып кала...

Атом реакторлары урнашкан мәйдан исә кыямәт көнен хәтерләтә. Атом калдыклары саклана торган корыч баклар көлгә әйләнгән, йөз алтмыш тонна авырлыктагы бетон плитәләр, чәлпәрәмә килеп теткәләнеп, күктә очып йөри. Атом радиациясенә манчылган тонналы таш һәм тимер кисәкләре йөз илле метр ераклыкка очып барып төшәләр. Бөтен тирәякка миллионлаган кюри атом калдыклары тарала. Атом болыты бөтен «Маяк» комбинатын, хәрбиләрнең шул тирәдәге казармаларын, әсирләрнең агач баракларын, шәһәрнең үзен, Иртәш күлен, тирә-яктагы урман-кырларны, авылларны каплап китә. Киңлеге кырык чакрымга сузылган атом болыты, Иртәш өстеннән күтәрелеп, татар җирләре буйлап мең чакрымга сузыла, Чиләбе, Свердловский, Төмән өлкәләрен басып ала. Иртәштән нибары кырык чакрымда яткан Татар Караболагы авылы атом аждаһасының беренче корбаны була.

Атом болыты үтеп киткән җирдә шунда ук агачлар саргая, кибә-корый, чыршылар энәләрен коялар. Җир үлә. Су агулана. Бу зонага эләккән мал-туарларның терелэй тиреләре кубып төшә. Ялгышып атом аҗдаганына караган кешеләр-

нең итләре сөякләреннән аерылып, җан бирәләр. Иң зур зыянны промплощадка дип аталган җирдә яшәүче тоткыннар күрә — шартлау алар өстендә була. Могҗиза белән исән калган тоткыннарны шунда ук атом пычрагын җыярга ташлыйлар, алар белән беркем хисаплашып тормый. Солдатларны да кайнап торган атом казанына — реакторларны чистартырга ыргыталар, аларның күбесе моннан исән чыкмый, исән калганнары соңыннан рактан һәм нурланыш авыруыннан зур газаплар белән үлә. Янгын сүндерүчеләр эшләгән урыннарда да радиацион нурланыш секундына берничә мең микрорентгенга җитә. Бу кешеләр атом утында терелəй янып үләләр. Иртәш буйларында атом фаҗигасе Чернобыльгә караганда егерме тугыз ел алдан була һәм шартлау көче дә Чернобыльгә караганда йөзләрчә тапкыр күбрәк була. Әмма кешеләргә моның атом фаҗигасе икәнлеген әйтмиләр, гадәти авариягә генә кайтарып калдыралар. Дәүләт бөтен нәрсәне яшерә, шундый зур фаҗигадән дә сер ясый. Мәетләрне тиз-тиз җыеп күмәләр, аларның төгәл санын беркемгә әйтмиләр. Мал-туарның үләксәсен җыеп яндыралар, радиацияле эш коралларын юк итәләр. Турыдан-туры атом болыты астында калган авылларны, торак пунктларын башка урыннарга күчерәләр. Атом болыты артыннан Караболакка да битлек кигән сәер кешеләр, хәрбиләр кереп тула. Тирә-як авылларда мәхшәр көне башлана. Караболак авылы да үзенең кайгылы һәм авырулы яңа чорына керә...

## Тугызынчы бүлек

Татар Караболагы авылына шом керде...

Иртәш буендагы көчле шартлаудан соң, авыл халкының башына күсәк белән кундырган кебек булды. Гомер буе чирнең нәрсә икәнен белмәгән кешеләр урынга ятты, авылда әллә нинди сәер авырулар күренә башлады. Әмма Караболак халкының шундый гадәте бар — алар үзләренә килгән чирне кешегә белдерергә яратмыйлар, аны яшерәләр һәм күпләрнең өендә ни белән авырып ятканын башкалар белмичә дә кала. Тик бу юлы хәл яшерерлек түгел иде, чөнки бөтен авыл берьюлы интекте, барысының да авырулары бертөрлерәк иде — кан косу, эч китү, чәч коелу, үзәккә үтәрлек көчле сызланулар һәм баш авыртулары. Авылда хәтта кисәк кенә сукыраючылар, баш авыртуына түзә алмыйча, акылга җиңеләючеләр дә булды. Гөлҗиһаннар классыннан болай да сүз әйтергә куркып торган Рәшидә бөтенләй җиңеләеп, сакау булып калды. Һәр өй саен моңа кадәр күренмәгән шундый бер хәл иде. Караболак авылына, гомер булмаганча, шом керде. Халык моның ахыры ни белән бетәчәген көтә башлады.

Әмма бу афәтнең очы-кырые күренмиде, ул әле башланган гына иде...

Әмма кем авыл халкының авыруына карап торсын соң? Шартлауның икенче көнендә үк, үзләреннән сорап та тормыйча, аякта калган кешеләрне барысын да яңадан кырга кудылар. Берничә көн уттай янып урын өстендә аунагач, боегып, ябыгып калган Гөлҗиһан да мәктәп балалары белән яңадан Караболак кырына чыкты, дөресрәге, аларны анда милиция белән алып килделәр. Әмма бу юлы Гөлҗиһан бәрәңге кырын танымады. Бөтен җирдә милиция, бөтен җирдә солдатлар һәм ниндидер сәер кешеләр иде. Алар йөзләрен битлек белән каплаганнар, өсләренә озын ак халат кигәннәр, кулларындагы таяклары белән нидер үлчәп, тикшереп йөриләр. Әмма иң гаҗәбе әле ул түгел, иң сәере — аларга беркөнне генә алган бәрәңгеләрен яңадан җиргә күмәргә куштылар, сәбәбен әйтмәделәр. Моңа укытучылар да, балалар да бик аптырашты, яшелчә-бәрәңгене дә, үзләренең хезмәтләрен дә кызгандылар. «Нигә бу хәтле бәрәңгене әрәм итәсез?» — дип сораганга, милиционерлар: «Аны ашарга ярамый» — дип җавап бирделәр. Кыр уртасына тирән чокырлар казып, алар бәрәңгене дә, кишер-кәбестәне дә яңадан җиргә күмделәр.

Ә Гөлҗиһаннар милиция күрмәгәндә ул бәрәңгене барыбер пешереп ашадылар, укытучылар да, авыл халкы да ашады. Ялан кырда көне буе тагы нәрсә ашыйсың — эшләп арыгач, пешерделәр дә ашадылар. Биташ чишмәсеннән алып килеп, су эчтеләр. Авырудан балаларның күбесе бик хәлсезләнгән иде, тиз арыйлар, тиз ашыйсылары, эчәселәре килә. Җитмәсә, кыр өстендә әллә нинди соры-кара тузан, ул балаларның авыз-борыннарына керә, үпкәләренә утыра, аннан тагы укшыта, тагы костыра. Авыл балалары ялан куллары белән шул сәер тузан арасыннан бәрәңге җыялар, аларның нәни куллары канап, сыдырылып бетә. Бу балалар каннары, үпкәләре аша атом тузанын йотканнарын аңламыйлар әле, тән күзәнәкләренә мәңгегә радионуклидлар кереп утырганын белмиләр. Бу үтергеч атом калдыкларының тиздән аларның тәннәрен черетә башлаячагын, сөякләрен җимерәсен, каннарын агулыйсын башларына да китермиләр. Кая анда балалар, бу хакта аларның укытучылары, шул ук кырда эшләп йөргән әти-әниләре дә белми, авыл халкының мондый хәлне күргәне-ишеткәне юк, сорасаң, дөресен әйтүче дә юк. Алар җыйган яшелчә-бәрәңгене милиция шунда ук тирән траншеяга ташлата һәм ирләр күмеп тә куялар. Халык бу хәтле ризыкны нигә әрәм иткәннәрен һаман аңлый алмый, чөнки ул Иртәштә атом шартлаганын белми, кырдагы бу ризыкларның радиация белән агуланганын да белми.

Кырдагы бәрәңге, яшелчә шулай юк ителгәч, халык үз бакчасында эшкә тотына. Монда инде юк итәргә дигән әмер юк, бәрәңгене берәмтекләп җыеп, базларга салалар, яшелчәләрне дә урнаштырып бетерәләр. Аларны чыгарып атарга беркем җыенмый, чөнки халык аларның да атомлы икәнлекләрен белми. Белсә дә нәрсә эшләр иде — чөнки аның бар карап торганы шушы бәрәңге дә, абзардагы мал-туары. Ә алда озын салкын Урал кышы, Караболак халкы аңа әзерләнеп, ризыклы булып керергә өйрәнгән. Ә быел әнә барысының да асты-өскә килде. Авыл тулы милиция, хәрбиләр, битлек кигән сәер кешеләр. Барысы да нәрсәдер тикшерә, үлчи, эзләнә. Нәрсә кирәк аларга Караболакта, нигә халыкка дөресен әйтмиләр алар, ни көтә быел кыш Караболак халкын? Беркем берни белми.

1957 елның октябреннән башлап, Татар Караболагы авылында коеларны күмә башладылар. Халык монысына бөтенләй шашынып калды — авылда коесыз, сусыз ничек яшәмәк кирәк?!

— Бу суны эчәргә ярамый, чөнки моннан нефть таптылар, — дип ялганладылар аларга битлек кигән адәмнәр. — Һәм сезне тиздән башка урынга күчерәләр...

Бу хәбәр Караболак халкын өнсез итте. Ничек башка урынга күчерәләр? Бөтен авыл беләнме? Кая күчерәләр? Ник күчерәләр? Нигә дип күчсеннәр алар Караболактан, кая күчсеннәр, дөньяда булмаганны!

Халык әнә шулай ярсыды, күтәрелеп бәрелде. Әмма авыл урамнарында һәр йөз метр саен мылтыклы сакчылар бастырып чыккач, халык сагаеп, тынып калды. Болайга киткәч, эшләр бик җитди булуын аңлады алар. Ул арада килгән битлекле кешеләр бөтен җиргә язулы такталар утыртып чыктылар — елга буена барырга ярамый, аннан су эчәргә ярамый, коеларны ачарга ярамый, кырда мал йөртергә ярамый. Ә ничек яшәргә авыл халкына — анысын беркем әйтми иде. Иң куркынычы — авылны төрмәдәге кебек чәнечкеле тимерчыбык белән уратып алдылар, аннан кереп-чыгып йөрү тыелды. Районнан әллә кемнәр килеп, кемдә күпме мал-туар бар, каралты-курасы нинди, җан башы ничә — өй саен язып йөри башладылар. Моның барысын да күчерү өчен эшлиләр, имеш. Нефть тапканнар дигән сүзгә Караболак халкы бик ышанып та бетмәде, чөнки нефтьне битлек киеп эзләмәгәннәрен беләләр иде алар. Бераз укыганнар, читтә йөреп кайтучылар, сугышта булганнар эшнең нефтьтә түгеллеген чамалыйлар иде. Болар барысы да Иртәш белән бәйләнгән, әмма нәрсә булган анда — әйтүче дә, белүче дә юк. Әйтерсең лә ахырзаман купкан — әле теге авылны күчергәннәр дигән хәбәр килеп ирешә, әле бу авылны урыннан кубарып әллә

кайларга илтеп ташлыйлар. Халык һәр көн бер-бер хәвефле хәбәр көтеп яши.

Чын мәгънәсендә ахырзаманны Нәбиулла үзләреннән ерак түгел урнашкан Бирдәнеш дигән татар авылында күреп кайтты. Ул бу хәлне гомеренең ахырына хәтле онытмас, мөгаен. Нәбиулла хәтта сугышта да мондый вәхшилекне күрмәгән иде. Бирдәнешкә ул шул көзнең ахырында колхоз эше белән барып чыккан иде. Караболактан чыкканда, кырык кат тикшерелеп, Бирдәнешкә килеп кергәндә, тагы шуның кадәр тентелгәннән соң гына ул колхоз йомышын йомышлый алды. Хәзер район буенча, авыл араларында йөри торган түгел, бөтен җирдә тикшерү, бөтен җирдә сакчы, беркемгә бернәрсә әйтү юк. Бирдәнеш халкы да кырмыска оясы кебек актарылып ташланган, кайнап тора иде. Инде исән-имин вакытта кайтып китим дип торганда, Нәбиулла авылны НКВД солдатлары чорнап алганны күрде. Ул авылдан чыгып китәргә өлгерә алмый калды, аннан беркемне чыгармыйлар иде. НКВД солдатларына төрмә тоткыннары булыша, алар авыл халкын, ирләргә-хатыннарга аерып, ат абзарларына таба куа башладылар. Беркемгә берни әйтү-аңлату юк, сугыш вакытында фашистлар ничек кылансалар, урыс солдатлары да шулай эшли. Авылда мәхшәр купты. Мылтыклы солдат Нәбиулланы да җилтерәтеп арбасыннан тартып төшерде, этәтөртә аны ирләр төркеменә куып кертте. Нәбиулла, гарип кулын селтәп, үзенең бу авылныкы түгеллеген аңлатырга тырышса да, аны тыңлаучы булмады. Татар авылы урысча сүгенгән, татарча такмаклап елаган, гарәпчә сузып тәкбир әйткән авазлар белән тулды... Күпләр, үлемебез шушы икән, дип уйлап, муеннарына кәфенлекләрен чорнап, өйләреннән чыга башладылар. Ул арада авылның бөтен хатын-кызын озын ат абзарына, ир-атларны ашлык амбарына куып керттеләр. Нәбиулла да Бирдәнеш ирләре төркемендә иде. Һәм татарлар өчен мәңге онытылмаслык хурлыклы мәхшәр башланды...

Аларның барысын шәп-шәрә итеп чишендерделәр дә өсләренә янгын машиналарыннан сасы салкын су сиптерә башладылар. Нәбиулла аның хлор икәнен сизеп алды. Бернәрсә аңламаган халык шашынып кычкырырга тотынды, ак сакаллы намаз картлары ил алдында шәрә калу хурлыгыннан җиргә чүктеләр, ир балалар, котлары чыгып, аталарына килеп ябыштылар. Тазарак ирләр, яшь егетләр бикле ишекне дөбердәтә, картлар үлемгә хәзерләнә, балалар ярсып елый башлады. Салкыннан, бугазларга ябышкан әче истән, шәрәлек оятыннан һәм билгесезлектән татар ирләре күккә карап үкерә, сугымга бәйләп салган мал кебек бәргәләнә иде. Нәрсә соң бу, ни өчен, аларны алга таба ни көтә — беркем берни

белми. Картлар яхшы хәтерли — патша заманында бу якларда татарларны шулай авылы-авылы белән амбарларга бикләп ут төртеп яндырганнар, Себер сөргәннәр, мөселман булган өчен генә очлы казыкларга утыртканнар, телләрен, борын-колакларын кисеп алганнар. Әллә, Ходаем, шул заманнар кире кайттымы, алар, авылда ятып, белмичә калдылармы икән?

Ул арада аларның өс-башларын сарай алдында ут төртеп яндырдылар, үзләренә бөтенләй ят, сасы исле киемнәр бирделәр. Советча дезинфекция тәмам булды. Нәбиулла да боз булып каткан тәненә чит-ят киемнәр киеп, сарайдан тышка атылды. Исән калганына сөенгән халык, сарык көтүе кебек, бер читкә барып өелде. Хлорлы салкын судан исән чыккан авыл хатыннарын үз ирләре дә таныйрлык түгел иде, аларның өсләрендә дә чит-ят сәләмәләр. Бу ике төркем, котлары чыгып, бер-берләренә якын килергә куркып, өелешеп бастылар.

Ә авылда...

Авылда тагы да куркыныч хәлләр. Ахырзаман үзе — мәхшәр мәйданы. Кешеләрнең күз алдында аларның өйләрен ут төртеп яндыралар, беркемне бернәрсә алырга якын җибәрмиләр. Бу хәлләрне күреп, кемдер үкереп елый, картлар тагы тәкбир әйтә башлый, маллар акыра, солдатлар кычкыра, шарт-шорт һавага аталар. Бу өйләрдә кешеләрнең гомер буе җыйган мал-мөлкәтләре, нәсел тарихлары, китаплары, Коръәннәре дөрләп яна. Аларның бар «гаепләре» — Иртәштәге шартлаудан соң атом болыты астында калулары. Әмма халыкка моны әйтмиләр, кешеләр ни өчен өйләренең дөрләп януларын белмиләр, аларны, кыймылдатмыйча да, мылтыклы солдатлар саклап тора.

Ул арада авылдагы бөтен терлек-туарны җыеп, алдан казып куйган тирән траншеяларга атып төшерә башлыйлар. Үлем исен, кан исен сизгән маллар аяк терәп үкерә, авыл буйлап хуҗаларын эзләп чаба башлый, аларны кыйный-кыйный яңадан тирән чокыр буена куалар. Нәбиулланың туры айгыры да шушы мәхшәргә эләккән булып чыкты, аны арбасы-ние белән үләт базына атып төшерделәр, аның үлем ачысы белән ярсып кешнәве Караболак буйларына хәтле барып җитте. Нәбиулла аның өчен берни эшли алмады. Бу мизгелләрдә ул үзе дә сугымга салынган мал хәлендә иде...

Бирдәнеш исә төрле баштан гөрләп янып килә. Әнә агач мәктәп яна, борынгы мәчет дөрләп яна, клуб, фермаларга ут каба. Мескен тоткыннар, бер өйдән икенчесенә йөгерә-йөгерә, ут төртеп йөриләр, аларның артыннан мылтыклы солдатлар куа. Халык инде дәшми. Халык инде моның белән килешкән. Халыкның берни эшләргә дә чарасы юк. Хәзер ин-

де еламыйлар да, берни сорамыйлар да. Барысы да бу мәхшәрнең ахырын көтә. Берни аңламаган, шашынган кешеләрне алдан әзерләнгән йөк машиналарына төяп, ашыга-ашыга Бирдәнештән алып чыгып киттеләр. Авыл аларны дөрләп янган өйләре, үләт базында үлә алмыйча үкереп яткан хайваннары белән озата кала...

Коншактагы бер агач казармага илтеп ташлагач кына, Нәбиулла бу төркемнән аерыла алды, шул көнне үк, җәяүләп, Караболакка кайтып китте. Ул авылны башка урынга күчерүнең нәрсә икәнлеген үз күзләре белән күрде, Караболакның алда торган язмышын уйлап, кара кайгыга төште. Бу күчерелүчеләр дә кая барасыларын, кайда торасыларын белмиләр, алар салкын кышка таба бер кат чит киемнән калдылар. Бу татарларның торырга өйләре юк, кияргә киемнәре, ашарга ризыклары юк. Караболакка да шушы кара язмыш әзерләндеме икәнни?

Шулай итеп, атом шартлавыннан зарар күргән авылларны башка урыннарга күчерә башладылар...

Әмма бу күчерү халыкны берни алдырмыйча, өйләреннән куып чыгаруга әйләнеп калды. Аларны ялан кырда ашыкпошык әвәләнгән фанер-такта йортларга, баракларга кертеп тутырдылар, беренче кышта ук күченгән халыкның күбесе ачлыктан, төрле чирләрдән кырылып бетте. Чөнки атом болыты астында калган бу кешеләрнең барысына да диярлек инде әҗәл тамгасы салынган иде, алар бөтен чир-зәхмәтләрне үзләре белән башка урынга да алып киттеләр. Мәңгелеккә алып киттеләр...

Шулай итеп, тирә-юньдә йөзләгән чакрым араны атом тузаны каплап китте, әмма моның шулай икәнен аерым кешеләр генә белә иде. Халыкка бу хакта берни дә әйтмәделәр. Атом тузаны, үлем нуры булып, меңләгән, миллионлаган кешеләрне, мал-туарны радиация белән агулап узды, авыл һәм кырларны каплады, җиргә сеңде, һавага таралды, суга китте...

1957 елның 29 сентябрендә «Маяк»та шартлау нәтиҗәләре шулкадәр коточкыч иде ки, хөкүмәт каршына хәтта бу атом комбинатын ябу-япмау мәсьәләсе дә килеп басты. Шартлауның икенче көнендә үк Иртәштәге Озерский шәһәренә Мәскәүдән зур комиссия килеп төште, аның составында генераллар, министрлар, галимнәр һәм табиблар бар иде. Тикшерү нәтиҗәләре шуны күрсәтте — шәһәр һәм комбинат радиоактив калдыклар белән бик пычранган, бөтен җирдә көчле радиация. Әмма иң куркынычы — шартлау вакытында радиоактив калдыклар саклый торган җайланмалар нык какшаган һәм аларның теләсә кайсы вакытта көлләре күккә очарга мөмкин. Аларның гына түгел, бөтен шәһәрнең, бөтен Урал буйларының атом шартлавы астында юкка чыгу кур-

кынычы бар иде. Биредә күпме атом бомбасы ятканын, күпме үлем коралы ясалганын, күпме радиоактив калдыклар саклангынын яхшы белгән комиссия зур проблема алдында калды. Илгә, кешеләргә зур куркыныч янавын истә тотып, СССР яки атом промышленностеннан, атом бомбасыннан баш тартырга, ягъни «Маяк»ны ябарга тиеш иде яки барысын да ничек бар — шулай калдырырга.

СССР машина төзү министры Е.Славкин приказы нигезендә, 3 октябрь көнне үк хәрбиләрдән ике зур отряд төзелә, алар шәһәрне һәм комбинатны атом калдыкларыннан чистартырга тиеш булалар. Әмма ничек итеп? Моңа кадәр беркемнең дә мондый хәлне күргәне юк, күзгә күренмәгән атом нурын ничек тотарга, ничек чистартырга — моны СССРда беркем дә белми. Әмма бу илдә кеше сансыз һәм кадерсез, аны теләсә нинди үлемгә каршы җибәрергә була. Хәтта атомга каршы да. Һәм солдатларны, исән калган тоткыннарны, көрәк һәм чүкеч тоттырып, атомга каршы җибәрәләр. Аларга янгын сүндерү машиналарында һәм бульдозерларда эшчеләр, төзүчеләр килеп кушыла. Күбесе бу атом казаныннан исән чыкмый, күзләре сукыраеп, тиреләре кубып, кан күзәнәкләре шартлап, шунда ук үлүчеләр була. Солдатларга һәм тоткыннарга исә, авария нәтиҗәләрен бетергәннән соң, өйләренә кайтарып җибәрергә вәгъдә бирәләр. Алар, радиоактив нурлар арасына кереп, зарарланган биналарны җимерәләр, атом нурыннан корыган агачларны, радиацияле бөтен чүпчарны җыеп, атом каберлекләренә күмәләр. Атом дулкыны үткән җирләрдән егерме сантиметр калынлыкта туфрак кырып алына һәм тирән чокырларга күмелә. Бу куркыныч эшләрнең барысын да солдатлар һәм тоткыннар башкара. Аларның һәр көн саен өс-башларын, резин итекләрен алыштырып торалар һәм җиргә күмәләр, чөнки алар да меңләгән микъдарда радиация сеңдергән булалар.

Тирә-як авылларда кешеләр һәм мал-туар урам уртасында егылып үлә башлагач кына, хөкүмәтнең кулы аларга да барып җитә — шул елның октябрь аенда ук егерме өч авыл башка урынга күчерелә. 102000 кеше радиацияле өйләреннән чыгарыла. 267000 квадрат километр җир яраксызга чыгарыла, йөз тонна авыл хуҗалыгы продукты юк ителә. Әмма хөкүмәт, белә торып, «Маяк» тирәсенә урнашкан һәм көчле радиациягә эләккән зур-зур татар авылларын башка урынга күчермичә, үле зонада утыртып калдыра. Ул вакытта бишәр мең татар яшәгән Мөслим, Үзбәгәрәк, Татар Караболагы авыллары атом зонасында тәҗрибә үткәрү өчен калдырыла. Халыктан басу-кырлар, көтүлек җирләре тартып алына, елгаларга коралллы сакчы куялар, бу авылларда бөтен төзелеш эшләре тыела. Ә ничек яшәргә мондый шартларда — аны-

сын беркем аңлатмый. Аның каравы атом шартлауга, Чиләбе, Мәскәү институтларыннан галимнәр һәм табиблар килеп, бу татарларны тикшерә, өйрәнә башлыйлар. Юк, бу мескеннәргә ярдәм итү өчен өйрәнмиләр аларны, ә бәлки, атом сугышы була калган очракта, кеше организмының кайсы якка үзгәрүен белү өчен тикшерәләр. Сталин, Берияләр әзерләп калдырган Ткаченколар командасы бу эш белән үзе җитәкчелек итә һәм ул дәүләт сере итеп саклана.

## Унынчы бүлек

Татар Караболагы авылы халкы, утка төшкәндәй, авылны күчерүне көтә.

Күчүең яхшымы, күчмәвең яхшымы — беркем аңламый, чөнки беркем дә күчерүнең сәбәпләрен белми. Күрше авыллардан берсеннән-берсе куркыныч хәбәрләр килеп тора, ул күчерү вакытындагы хәлләрне сөйләп бетерә алмыйлар. Бүген-иртәгә күчерүне көтеп яткан Татар Караболагы авылына шом керде, һәркемнең эченә ут төште. Килгән килмешәк Караболакны ташлап кача башлады, төп халык нәсел-нәсел, күч-күч киңәшмәгә җыелды. Нишләргә? Гомер иткән ата-бабалар нигезен ташлап ничек кузгалырга, кая барырга? Әнә күчкән кешеләр бер дә сөенмиләр бит — бернәрсәсез как кырга илткәннәр дә ташлаганнар аларны. Кемне — җир землянкаларга, кемне такта алачыкларга куып керткәннәр. Ә алда — салкын Урал кышы, ничек чыгар алар бу кышны? Татар Караболагы авылы халкын да шундый язмыш көтәме? Меңәр ел шушы җирдә яшәгән борынгы халыкны, затлы Хан нәселләрен буш далада ачтан бетләп үлү, тереләй кабергә керү көтәме? Миллион еллык күл-сулары, меңәр еллык курган-каберләре булган Татар Караболагы авылын юкка чыгу көтәме? Һәркем бүген шул сорау алдында калган иде...

Нәбиулланың олы нәселе дә киңәш-табышка җыелды. Карттайлар һәм картнәйләр, атай-инәйләр, абзый-җиңгиләр, бала-чагалар берсе дә бу сөйләшүдән читтә калмады. Ярулла картның бертуган энесе Таһирҗан әзине дә чакырдылар, чөнки нинди заманда да намазын ташламаган ир уртасы бу кеше үзенең зирәк акылы, әдәп-әхлагы белән бөтен тирә-якта аерылып тора иде. Аны, үзе югында, «Караболак әүлиясы» дип йөртәләр иде...

— Йә, нишлибез, әзиләр? — диде Нәбиулла, бөтен туган-тумача җыелып беткәч. — Галикәй, Бирдәнешләр кебек, авылга ут төртеп чыгып китәбезме, монда калып бетәбезме? Әйдә, киңәшик, нинди фикергә килсәк, шулай эшләрбез.

Кинәт куелган бу куркыныч сораудан барысы да телсез-өнсез калды. Әйе, күпме генә сузсаң да, хәл шундый иде — китсәң дә бетәсең, калсаң да бетәсең. Ә ничек яшәргә соң алай булгач, ничек нәселне саклап калырга? Бу якларга күзгә күренмәгән куркыныч зәхмәт килгәнен алар аңлаганнар иде инде, Иртәштән Хәбибулла туганнары үләргә кайтып егылгач, бу афәтне үз күзләре белән күргән кебек булдылар.

Хәбибулла армия хезмәтен Иртәштә генә үтте, төзелештә иң авыр эшләрдә эшләде. Ул вакытларда әле шәһәргә кереп-чыгып йөрү ирекле түгел иде, Хәбибулланың бөтен гомере төрмәдәге кебек биктә үтте... Армия хезмәтеннән соң да Хәбибулла шушы ябык шәһәрдә калды, Таифә исемле татар кызына өйләнде, һәм алар яшәргә дә Иртәштә торып калдылар. Заманалар бераз үзгәреп, шәһәрдән читкә чыгарга рөхсәт булгач, Хәбибулла гаиләсен, ике баласын Караболакка алып кайтып күрсәткән иде. Ата-ана нишләсен, төп нигездә калырга тиешле төпчек малай Хәбибулла шулай итеп яшерен шәһәрдә урнашты да калды. Әкренләп Хәбибулла Иртәш читендә үзенә агач йорт җитештереп куйды, анда яшәргә генә насыйп булмаган, күрәсең...

Менә шул Хәбибулла, Иртәштәге теге шартлаудан соң, авырып авылга кайтып егылды. Әзмәвер кебек ир-ат кипкән балык хәленә калып ябыккан, беткән иде. Аның башында бер бөртек чәче калмаган, йөзе саргаеп кипкән, күзләренә кып-кызыл кан сауган, еласа да, кан агып чыгар кебек. Үзе берни сөйләми, кайда мондый хәлгә калганлыгын әйтми, көннәр буе түшәмгә карап, сызланып ята. Хәбибулланың мондый хәлгә төшүе бөтен нәсел өчен кара кайгы булды, атом афәте бу нәселдә дә үз исәп-хисабын ачып җибәргән иде.

— Нишлик, энекәш? — диде Нәбиулла, үлем көтеп яткан туганына карап. — Китикме, калыйкмы? Анда ни сөйлиләр? Бу афәтне туктатырлык хәлләре бармы Иртәштә?

Хәбибулла дәүләт серен ачмаска егерме биш елга кул куйган кеше. Дөрес, ул андый зур дәүләт серләрен белми, әмма мәхшәрне үз күзләре белән күреп кайтты. Әле ярый аларның өйләре «Маяк»тан шактый еракта, шәһәр читендә иде, балалар белән базларга, идән асларына качып котылдылар. Промплощадкага якын торучылар исә кырып салган кебек булды, үлүчеләрнең санын хәтта әйтеп тә тормадылар. Ул тирәдә җимерелмәгән бер йорт, бер бина калмаган иде. Халык төрлесен сөйләде, кем, реакторлар шартлаган икән, диде, кем, атом бомбасы шартлаган, диде. Махсус сынау уздырганнар икән, диючеләр дә булды. Шартлауның икенче көнендә үк аларны бригадалары белән шул җимерекләрне чистартырга җибәрделәр. Менә шунда күрде инде Хәбибулла дөнья бетүнең нәрсә икәнен, менә шунда алды инде ул әҗәл чирен.

Әле дә күз алдында аның — атом шартлаган урында җирнең үзәге, эче актарылып чыккан, таш-тимерләр эрегән иде... Бөтен нәрсәгә кул яссуы агулы тузан утырган. Солдатлар һәм тоткыннар белән берлектә, төзүче татарлар да әнә шул агуны җыештырдылар, атом тузанлы нәрсәләрне кайсын җиргә күмделәр, кайсын ут төртеп яндырдылар. Күпләр шул көнне үк кан косып ауды, күпләрне носилкалар белән алып киттеләр, алар урынына яңаларны куып керттеләр. Анда беркем сорап тормый синнән, эшләргә телисеңме, юкмы, дип... Нинди куркыныч булуын да әйтмиләр. Эшкә чыкмасаң — төрмә, ә анда утыручылардан сорап та тормыйлар, аларны атом казанының эченә ыргыталар.

Хәбибулла бу мәхшәрдән могҗиза белән генә исән калды, әмма чирнең катысын эләктерде. Шунда ук бетмәвенә авыл тазалыгы ярдәм иткәндер инде, ул үзе дә сак булырга тырышты. Әмма ул гарасаттан сакланып бетеп буламы соң — һавада, суда, туфракта шул агу булганда? Димәк, бу зәхмәт Караболакка да килеп җиткән икән. Иртәштәге хәлләр монда да башланырга мөмкин, андагы чирләрнең бирегә дә килеп җитүе бар. Трактор белән коеларны күмеп йөриләр икән, димәк, аның суын эчәргә ярамый, ул агулы. Көтүлекләргә мал керттермиләр икән, димәк, туфрак та агулы, анда үскән үсемлекләр дә агулы, аны ашаган мал-туарның ите-сөте дә кулланырга ярамый. Димәк, биредә яшәргә ярамый.

— Иртәштә мәхшәр, туганнар, — диде ул, боларны искә төшергәч. — Кыямәт көне анда... Әмма мин аларны сезгә сөйли алмыйм, ярамый... Син, әзи, солдатта булган кеше бит инде, сугышны күргән... Менә шундый хәл анда... Атом сугышы узган кебек...

Ирләр бер-берләренә карашып алдылар. Хатын-кызлар, хәвефләнеп, аларның нинди карарга килүләрен көттеләр, чөнки алар ничек әйтсә, шулай булачак иде. Авырудан яңа терелеп килгән Гөлҗиһан да шомланып калды, йөзе җитдиләнде, уйчанланды. Караболакны ташлап китү уе аның котын ала иде. Ничек Караболакны ташлап китәргә мөмкин инде, мондый авыл башка бер җирдә дә юк бит! Биташ күлләрен, аның шифалы чишмәләрен, борынгы тау куышларын, Алып Ханнарның кабер-курганнарын кемнәргә калдырып китәсең?! Кая китәсең? Гөлҗиһанның бер җиргә дә китәсе килми Караболактан, ул үлсә дә шунда калырга риза. Күк капусы ачылганда да ул бары тик шуны гына теләде бит — Караболак мәңге булсын, әти-әнисе, әби-бабайлары гел исән булсын дип теләде. Аның бу теләге кабул булмадымы икәнни?

Гөлҗиһан, мөлдерәп, Таһирҗан бабасына карады, чөнки ул ни әйтсә дә, дөрес әйтә. Аны бөтен авыл әүлия дип атый, ул белергә тиеш бит инде нәрсә эшләргә кирәклеген.

— Алай икән... — дип куйды Таһирҗан карт, аның уйларын сизгәндәй. — Мәхшәр, дисең алайса, Хәбибулла энекәш. Монда әле алай ук түгел түгелен, әмма дөнья үзгәрде монда да. Бу хәзер элеккеге Караболак түгел инде. Кешеләр үзгәрде. Холык-фигыльләре үзгәрде. Авылда хәвеф-борчу күп. Чирләр күбәйде, әллә нинди ят чирләр. Кинәт үлемнәр күренә башлады. Бу — шуның тәэсире инде, шуның.

«Нәрсәнең тәэсире?» — дип сорыйсы килсә дә, Гөлҗиһан тынып калды. Ул бала акылы белән дә сизенә иде — Иртәштәге шул шартлаудан соң бөтен авыл авырый башлады бит инде, коеларны күмделәр, кырдагы бәрәңгеләрне юк иттеләр. Сорасаң, «Ярамый!» гына диләр, ә нигә ярамаганын әйтмиләр. Хәтта укытучылар да берни әйтми, бәлки, алар үзләре дә белмиләрдер әле. Таһирҗан бабай да әйтмәгәч, чынлап та, әйтергә ярамыйдыр инде аны.

— Нишлик соң, Таһирҗан әзи, китәргәме, калыргамы безгә Караболакта? — дип, туп-туры сорап куйды Гөлҗиһанның әтисе.

— Җибәрә башласалар, калам дисәң дә кала алмассың, Нәбиулла энем, — диде Таһирҗан карт, сабыр гына. — Бирдәнешне ничек күчергәннәрен үзең кайтып сөйләдең бит, теләсәләр, безне дә бер сәгатьтә шулай кырга чыгарып ата алалар. Әнә күрше Урыс Караболагын бер көндә шулай күчерделәр, өйләрен ут төртеп яндырдылар, ялкыны монда күренеп торды. Элек чума чире, ваба вакытында шулай кыланалар иде. Димәк, бу аннан да куркынычрак зәхмәт инде. Калсаң да куркыныч, китсәң дә ул сиңа кагылып өлгергән инде... Нишләргә дә белгән юк, балалар. Аллаһтан хәерлесен сорыйк. Китәргә язган икән — китәрбез, калырга язган икән — туган туфракта җан бирербез.

— Нигәдер безгә кагылмыйлар әле, — дип, сүзгә кушылды Ярулла карт та. — Югыйсә Урыс Караболагы безгә терәлеп кенә тора бит инде. Әллә безне күчермәскә булдылармы икән соң? Кышка каршы кая куйсыннар мондый зур авылны? Бәлки, хәзергә кагылмаулары да хәерледер, белүче Аллаһы Тәгалә генә...

— Күчерәбез дип әйттеләр шул, әти, — диде Нәбиулла. — Коншакка барганда, ишеткәләп кайтам — бу тирәдәге бөтен урыс авылларын анда-монда таратып бетергәннәр инде, берничә татар авылын да күчергәннәр. Ә нигәдер Мөслим, Үзбәгәрәк, Татар Караболагы кебек зур-зур авылларга һаман тотынмыйлар. Бәлки, шул зурлыклары куркытадыр, кая куеп бетерсеннәр кышка каршы бу хәтле халыкны. Бәлки әле, бөтенләй күчермәсләр дә, шул килеш калдырырлар...

Гөлҗиһан сөенеченнән урыныннан ук сикереп торды. Әйе, күчермәсеннәр шул Караболакны, Гөлҗиһаннар да монда кал-

сыннар! Ул хәзер авырмый бит инде, терелде, аның Караболакны ташлап, бер җиргә дә китәсе килми.

— Бу зәхмәт бөтен тирә-юньгә таралды инде, ыланнар, — диде Таһирҗан карт, уйчан гына. — Кая күчсәң дә, ул безнең белән ияреп барачак. Кая барсаң да, шушы хәл булуы мөмкин. Галикәйләрне биш-алты чакрымдагы ялан кырга илтеп ташлаудан ни үзгәрер икән соң алар өчен? Бу күчерү дигәннәре дә күз буяу өчен генә булырга охшаган, ягъни «күчердекме — күчердек». Ә бу зәхмәтне кая куясың, тамгасы һәр кешедә инде аның хәзер.

Таһирҗан картның ни әйткәнен аңлап бетермәсәләр дә, барысы да, тын алмыйча, аны тыңладылар. Ул ни әйтсә дә, җаен белеп, иплəп әйтә, бөтенесен уйлап сөйли. Ул үз тәкъдиренә дә, авыл язмышына да ышана, шуңа күрә Аллаһтан да үзләре өчен хәерлесен сорый. Ә адәм баласына нәрсә хәерле икәнен бер Аллаһ кына белә.

— Мәҗбүри кумасалар, нигез ташлап, авыл ташлап йөреп булмас, ыланнар, — дип дәвам итте Таһирҗан карт, төпле бер карарга килгәндәй. — Шушы шартларда яшәргә, исән калырга өйрәник. Бу безгә Аллаһның бер сынавы яки җәзасыдыр, мөгаен. Авылдан дин чыгып бара, кешеләрдән иман китә, шуңа җавап инде бу хәлләр, әмма моны күпләр аңламый шул, аңламый. Җирдәге шушы газаплар аша, бәлки, халык иманга, тәүбәгә килер, ахирәт көнендә җәннәтләргә ирешер. Югыйсә пәйгамбәрләр аяк баскан җир бит бу Караболак тирәләре, сәхабәләр, әүлиялар яшәгән изге җир. Җәһәннәм уты да шушында бәреп чыгар дип кем уйлаган.

Аның бу сүзләреннән карт-карчыклар авыр гына көрсенеп куйдылар, ирләр тынып калды, хатын-кызның, бала-чаганың эченә шом керде. Таһирҗан карт, серле сөйләсә дә, белеп сөйли ул. Һәрвакыт дөресен сөйли. Шуңа күрә аны «Караболак әүлиясы» дип йөртәләр дә инде. Ул шулай уйлый икән, димәк, шулай була — Гөлҗиһаннар бер җиргә дә китми, Караболакта кала. Караболак та үз урынында кала, чөнки Таһирҗан бабай, аны күчерәләр дип, өздереп әйтмәде бит. Димәк, Таһирҗан бабай әйткәнчә, шушы шартларда яшәргә, исән калырга өйрәнергә кирәк.

Шулай итеп, Алып Ханнар нәселе җыелып киңәш иткәннән соң, моңа кадәр ничек яшәгәннәр, шулай яшәргә ният иттеләр. Бәргәләнмичә-өзгәләнмичә, вәсвәсәгә бирешмичә, шул ук вакытта саклык чаралары да күреп, үзләренчә яшәп карарга булдылар. «Ни күрсәк тә, ил белән бергә күрербез» дип уйлады алар. Ә Караболак халкының берсенең дә каядыр күчәргә исәбе юк иде, туган илдән, туган җирдән мәңгегә аерылып китү алар өчен үлем белән бер иде.

Шулай итеп, билгесезлек эчендә 1957 елның коры көзе үтте, Караболак халкы озын салкын кышка керде.

Кар төшкәнче олысы-кечесе кырда булды — бар бәрәңгене, яшелчәне җыеп, тирән чокырларга күмделәр, атом тузаны утырган эскерт өсләрен төшереп яндырдылар, бушап калган җирләрне тирән итеп сөреп чыктылар. Ниһаять, ноябрь урталарында беренче кар яуды, атомлы кырлар, яндырылган авыллар, җимерек хәрабәләр барысы да ак кар астында күмелеп калды. Әмма Караболак халкына эш бетмәде, алар кыш буе кырга эскерт өстен төшерергә йөрделәр, аннан күтәрелгән яшелле-зәңгәрле төтенгә тончыгып, аңнарын югалтып егылучылар, хәтта үлүчеләр дә булды. Монда да авыл халкын хәрбиләр карап торып эшләтте, колхозчылар аларның әмеренә буйсынырга тиеш иде. Караболак халкы эскертнең өске — агулы өлешен ут төртеп яндыралар иде дә, көлен җиргә күмәләр иде. Калган саламны исә хәрбиләр колхозчыларга бушка алырга рөхсәт итәләр иде. Авыл халкы ул чагында үз куллары белән абзарларына кырдан радиацияле печән-салам ташыганнарын белми, әлбәттә, ә белүчеләр аларга бу хакта берни дә әйтми. Шулай итеп, Караболак халкы үз куллары белән кыш буе кырдан үзенә үлем ташыды.

1958 елның маенда, җир кардан арыну белән үк, Татар Караболагы авылы халкын тагын мәҗбүри эшкә куа башладылар. Бу юлы Урыс Караболагы авылын атом пычрагыннан чистартырга тиеш иде Караболак татарлары. Хәрбиләр бар халыкны — олысын-кечесен, мәктәп балаларын, хәтта авырлы хатыннарны, мылтык астында Урыс Караболагына куып китерделәр. Ниндидер сәбәп белән бу эшкә чыкмаган кешеләрнең утырткан бәрәңгеләрен сукалатып ташладылар, малларын көтүгә чыгартмадылар. Авылга хәрбиләр хуҗа булып алды, тыңламаучыларны төрмә көтә иде. Мондый хәлне гомерендә дә күрмәгән авыл халкы ике ут арасында калды — Урыс Караболагына эшкә барып, тагы чирләп кайтыргамы, әллә бармыйча калып, бер хокуксыз кешегә әйләнергәме, төрмәдә черергәме? Шулай башбаштакланган берничә гаиләне әнә авылдан куу белән үк яный башладылар. Һәм авыл халкы, аяклары тартмаса да, Урыс Караболагы авылына эшкә китәргә мәҗбүр булды. Ташландык урыс авылы аларны җимерек хәрабәләре, иясез этләре, шыксыз, кешесез урамнары белән каршы алды. Әйтерсең биредә зур сугыш булып үткән иде.

Урыс Караболагы авылы халкын, көзге шартлау белән үк башка урынга күчергәннәр иде инде. Биредә агач өйләр шунда ук яндырылып, мал-туар атып-үтерелеп бетерелгән иде. Әмма монда таштан һәм кирпечтән салынган берничә нык йорт, кирпеч мәктәп, таш чиркәү, кибет биналары бар

иде. Караболак татарлары менә шуларны сүтеп, җимереп, чүпчарны авыл буйлап казылган тирән чокырларга тутырырга тиешләр иде. Яхшырак кирпечләрне чистартып, Татар Караболагы авылына алып кайтырга куштылар, чиркәү ташларыннан анда дуңгыз фермасы төзеделәр. Әмма ул дуңгызлар бик тиз үлеп беттеләр, моның радиация тәэсире икәнлеген авылда белүче булмады. Хәрбиләр радиацияле кирпечләрне татарларның үзләренә дә алырга рөхсәт иттеләр, алар да Караболак авылына кайтып, үзләренең кара эшләрен эшли башладылар.

Гөлҗиһан да бөтен мәктәпләре белән Урыс Караболагы авылы хәрабәләрендә эшли. Монда балалардан да, укытучылардан да сорап тору юк, Урыс Караболагына мылтык белән төяп алып китәләр, мылтык астында кайтарып куялар. Гөлҗиһанның әти-әнисе дә биредә, Таһирҗан бабай да монда, эшкә чыкмасаң, бәрәңге бакчаңны сукалатып ташлыйлар. Шуңа күрә бөтен авыл Урыс Караболагын чистарта. Олылар кайда лом, кайда техника ярдәмендә таш биналарны җимерәләр, ә балалар, хатын-кызлар шул таш-кирпечләрне аерып, яхшыракларын кырып-чистартып, төрле өемнәргә өеп баралар. Хәрабәләрдән яшелле-зәңгәрле төтен күтәрелә, ул күзләргә, борыннарга керә, бугазга утыра, укшыта башлый. Моңа түзә алмаган балалар, йөгереп барып, Караболак елгасына ятып су эчәләр, бит-кулларын юалар. Елга ярларында «Эчәргә ярамый!» дигән кисәтү торса да, хәрбиләр моны күрмәмешкә салына. Көне буе җимерекләр арасында эшләгән кешеләр кайдан су эчәргә, нәрсә ашарга тиешләр соң? Кемдер, кайдандыр табып, учак ягып бәрәңге пешереп ашый, кемдер юл читендә котырып үскән әнис, какыларны өзеп каба. Гөлҗиһанга Таһирҗан бабасы моннан бернәрсә ашамаска кушса да, ул, кызыгып, какысына да, әнисенә дә үрелә. Балалар белән бергә, Караболак елгасына барып, юынып та килә. Чөнки бу суларда, бу үләннәрдә Гөлҗиһан бернинди үзгәреш күрми, элек ничек тәмле-татлы булсалар, алар хәзер дә шундый.

Гөлҗиһанны иң гаҗәпләндергәне кибет һәм чиркәү бинальары булды. Кибетнең эче тулы әйбер, хәтта прәннек-конфет та бар, әмма аларны ашарга ярамый икән — мылтыклы солдат саклап тора. Кибеттәге әйберләрне дә ташлаячаклар икән, чокырга күмәчәкләр, ди. Ничек инде шулхәтле әйберне чокырга күмәргә була? Анда ялтырап торган туфлиләр, шундый матур күлмәкләр, пәлтәләр дә бар бит! Их, шуларны Гөлҗиһанга һәм башка балаларга бирсәләр! Юырлар иде дә, киярләр иде әле. Прәннекләрен дә «ә» дигәнче ашап бетерерләр иде, барыбер бу авылда нәрсә бар — барысын да ашыйлар бит. Әмма авыл балалары кибет тирәсендә күпме

генә бөтерелеп йөрсәләр дә, аларга бернәрсә дә эләкмәде — кибетне каядыр төяп алып киттеләр. Аның каравы Гөлҗиһаннар чиркәү складларында бал белән тулы умарта кәрәзләре таптылар! Һәм аны бик тиз бүлешеп ашап та бетерделәр һәм су эчәргә тагы Караболакка йөгерделәр.

Бу чиркәү инде күптән чиркәү түгел, анда колхозның склады булган икән. Халык аны җимерә алмыйча иза чикте, ул шулхәтле нык иде. Башта көрәкләр, ломнар белән атна буе чокып карадылар — чиркәү ташлары селкенмәде дә. Аның измәсе моннан йөз ел элек йомырка сарысыннан эшләнгән булган икән, шул катырган ташларны. Унбиш ир-ат атна буе ломнар белән бәреп, тракторлар белән эттереп тә булдыра алмагач, солдатлар килеп, чиркәүне шартлаттылар. Чиркәү гөмбәзләренә, стеналарына утырган атом тузаны, шартлап, һавага очты, шунда эшләп йөргән татарларның башларына, өсләренә кунды. Кирпечләрне чистартырга мәктәп балаларын куйдылар, Гөлҗиһан да алар арасында иде. Алар, берни белмичә, ялан куллары белән радиацияле кирпечләрне күкрәкләренә терәп, бер кырыйга ташыйлар. Анда аларны кырып чистарталар, начарларын ирләр чокырга күмә, яхшыракларын Татар Караболагына озаталар. Халык иртәдән кичкә кадәр атом тузаны арасында эшли, тагы авыручылар, чирләп егылучылар күренә башлый. Әмма Урыс Караболагын тәмам чистартып бетермичә, татарларны моннан җибәрмиләр.

Инде эш тәмам бетте дигәч тә, яңасын уйлап табалар — мәктәп балаларын Урыс Караболагына агач утыртырга йөртә башлыйлар. Авылның буеннан-буена утырта алар аны. Чиләбе — Сверлау олы юлыннан бу җимерек хәрабәләр күренеп тормасын өчен, чокыр-чакырлар каплансын өчен, буйдан-буйга яшь карагайлар утырталар Караболак балалары. Гөлҗиһан да алар арасында була. Алар яланаяк, яланкул көенчә, берни белмичә, атом тузаны арасында йөгереп йөриләр. Шунда Караболак елгасына ятып су эчәләр, кырда бәрәңге пешереп ашыйлар.

Соңыннан билгеле булыр — Гөлҗиһаннар эшләгән Урыс Караболагы җирләрендә ул вакытта радиация бер квадрат метрга мең кюри туры килгән, нурланыш сәгатькә мең микрорентген булган... Гөлҗиһаннар классыннан монда эшләгән егерме тугыз баланың алдагы елларда унсигезе рактан һәм нурланыштан үлеп бетәр. Гөлҗиһан могҗиза белән исән калыр, шушыларны дөньяга чыгару өчен аның исән калуы кирәк булыр. Әмма ул да авылдашлары үткән газаплы юлны ахыргача үтәр, бу авырулардан ахыргача газапланыр...

Хәзергә әнә ул йөгерә-йөгерә агач үсентеләре ташый. Аның да кул-аяклары сыдырылып беткән, күзен-башын ак-

сыл тузан каплаган. Әле ярый Таһирҗан бабасы аңа иртә белән яулык бөркәтте, чәчләре чиста калды. Рәшидә белән Рабига да яулыктан, чөнки аларның чәчләре бөтенләй коелып беткән. Малайлар Рәшидәне үртиләр, яулыгын тартып төшермәкче булалар, ә ул гел Гөлҗиһанга сыена, аннан ярдәм көтә. Бу авырулардан Рәшидә бөтенләй сүзсезләнеп, телсезләнеп калды, аның нәрсә әйткәнлеге дә аңлашылмый. Аны көздән мәктәпкә алмаслар инде, йә Чиләбедәге тиле балалар йортына җибәрерләр, йә авылда укымыйча калыр. Әнә хәзер дә бу эчкерсез дивана кыз гел Гөлҗиһан тирәсендә йөри, ничек тә аңа ярарга, булышырга тырыша. Ә Гөлҗиһанның бүген иртәдән бирле башы әйләнә, күз аллары томаланып-томаланып китә. Теге вакытта Иртәштә шартлагач та шулай булган иде — эче борып-борып авыртты, авыз-борыннан кан китте. Хәзер дә Гөлҗиһанның башы шундый нык авырта, әйтерсең тимер кыршау белән тарттырып куйганнар! Аның авыртуыннан җиргә ятып тәгәрисе, үкереп елыйсы килә, әмма ул башкалардан ояла. Эшләрлек хәле дә юк. Укытучы абыйсыннан сорап, Гөлҗиһан Караболак буенда битен-күзен юып килергә уйлады. Бәлки, хәле бераз җиңеләеп китәр, чөнки әбисе авырганда, гел тизрәк юына, су эчә. Кичкә хәтле түзсә, өйдә әбисе дәвалар иде инде аны, әмма кичкә ерак шул әле.

Ул акрын гына су буена атлады, Рәшидә дә аның артыннан иярде. Гөлҗиһан аны күрмәде дә, чөнки ул инде беркемне, бернәрсәне күрерлек хәлдә түгел иде. Башта аяклары аны тыңламый башладылар, алар камыр кебек йомшардылар һәм Гөлҗиһан тизрәк яшь карагайлар арасына кереп чүгәләде. Көчле авыртуга чыдый алмыйча, ул үкшып җибәрде. Шулчак күзен-башын кемдер үткен пычак белән телеп җибәргән кебек булды, көчле авыртудан Гөлҗиһан агач арасына тәгәрәп китте. Башта аның күз алды гөлт итеп яктырды, каршында нәкъ теге вакытта күк капусы ачылган кебек булды. Әмма ул вакытта мондый авырту юк иде. Аннан кинәт кенә күз алды караңгыланды һәм Гөлҗиһан шул караңгы базга ава башлады. Зиһен бетте, авырту бетте, җан менә чыгам, менә чыгам дип, кызның күгәргән ирен читләрендә тибрәнеп тора башлады. Зәңгәр күк астында, яшел чирәм өстендә Гөлҗиһан атлы татар баласы туган җирендә җан биреп, үлеп ята иде.

Җаны аның тәнен туп-туры Караболак өстенә алып менеп китте...

Гөлҗиһан ап-ачык итеп үзләренең өйләрен, әби-бабасын, әти-әнисен күреп өлгерде. Алар барысы да Гөлҗиһанны көтәләр иде. Аннан ул зур тизлек белән Иртәш ягына таба оча башлады, анда үзенең булачак гаиләсен — ирен һәм балала-

рын күреп калды. Алар да Гөлҗиһанны көтәләр иде. Ул каршында ут һәм нур күрде, шулар арасыннан сызылып үткән сират күперен күреп калды. Шул турга җиткәч, җан кире борылды, чөнки Гөлҗиһанга аннан үтәргә әле иртә иде. Гөлҗиһан үкереп янган уттан бик курыкты, моның җәһәннәм икәнлеген аңлады. Каршында җемелдәп торган зәңгәр нур, киресенчә, аны үзенә тартты, әйтеп бетергесез рәхәтлек, ләззәт бирде. Гөлҗиһан аның җәннәт икәнлеген аңлады, нигәдер шунда керәсе, бөтенләйгә шунда каласы килде. Әмма җаны, аны тыңламыйча, томырылып аска очты, яңадан җиргә төште.

Башта аның янына озын бер бабай килде. Ул Таһирҗан бабасына бик охшаган, әмма ул түгел, чөнки бу зат бик озын. Ул Гөлҗиһан янына тезләнеп, нидер укый башлады. Нәкъ карттае, картнәе Коръән укыган кебек. Ә тавышы Таһирҗан бабасына охшаган. Ул укыган саен, Гөлҗиһанның хәле җиңеләя бара, күкрәген басып торган авырлык юкка чыга, ул тагы иркен сулыш ала башлый. Менә озын карт аның өстенә ныграк иелә дә нидер әйтә. Ә тавышы нәкъ Таһирҗан бабайныкы кебек. «Су эчмә... Ризык ашама... Монда торма...» — ди. Шул сүзләрне әйтә дә озын бабай юкка чыга. Гөлҗиһан, берни аңламый, зәңгәр күккә карап ята. Нигә елгадан су эчәргә ярамый икән? Монда ашарга да, яшәргә дә ярамый, ди. Ә кайда ярый? Шуны сорарга теләп, Гөлҗиһан күзләре белән озын картны эзли башлады, әмма ул юкка чыккан иде. Ә янында, тезләнеп, Таһирҗан бабай утыра, аның янында елап беткән Рәшидә басып тора.

— Теге бабай кайда? — дип сорады Гөлҗиһан, телен чак әйләндереп.

— Нинди бабай, кызым? Монда синнән башка беркем юк иде. Рәшидә эзләп табып, мине монда өстерәп алып килде, әле ярый машина белән үсентеләр китергән вакытым иде. Кай төшең авырта соң, балам?

— Теге вакыттагы кебек... — диде Гөлҗиһан, хәлсез генә. — Башым бик авырта, бабай.

Гөлҗиһан шулай диде дә тагы укшып җибәрде. Таһирҗан карт аның маңгаена кулын куеп карады — Гөлҗиһанның башы ут булып яна иде. Аннан ул ялкын кызның битләренә күчте, тәнен чорнап алды. Ул инде янында беркемне күрми, бары тик нидер әйтеп саташа гына иде. «Моннан су эчмә... Ашама... Яшәмә... Озын бабай...» Бу хәлне күреп, Рәшидә тагы үкереп елый башлады, кырга, укытучылары янына торып йөгерде. Таһирҗан карт Гөлҗиһанны тиз генә кулларына күтәрде дә машинасына таба йөгерде. Лесник хатын Мария белән бергә алар Гөлҗиһанны авылга алып кайтып киттеләр. Гөлҗиһанның инде тын алганы да беленми, тәнен-

нән ут бәреп тора иде. Шушы хәлендә аны өйләренә алып кайтып салдылар. Кайтып кергәндә, аның тәненнән тиресе куба башлаган иде инде. Моны күреп, әнисе аңын җуеп егылды, әбисе елап ук җибәрде. Ир-ат мәет күмәргә әзерләнә башлады, чөнки Караболакта мондый авырулардан берсе дә исән калмый иде. Таһирҗан карт аларга ашыкмаска кушты, «Баланың гомере бетмәгән әле...» — диде. Унике яшьлек Гөлҗиһан яшәү өчен үлем белән көрәшә башлады. Бу көрәш кырык көн, кырык төн дәвам итте.

## Унберенче бүлек

Татар Караболагы авылын тагы көне-төне ак маска-халатлар, противогазлар кигән сәер кешеләр тикшерә башлады.

Аларның приборлары радиациянең биредә йөзләрчә, хәтта меңнәрчә тапкыр артык икәнлеген күрсәтте. Авылда тагы кинәт кенә кешеләр чирли һәм үлә башлады, әйтерсең лә Караболактан үләт үткән. Бу мәетләрне Чиләбегә алып китәләр дә, эч-башларын ярып, күмәргә буш гәүдәләрен генә кайтаралар. Хәтта сөякләренә хәтле суырып алалар. Халыкның нидән шулай кырылганлыгын беркемгә дә әйтмиләр, «Тикшерәбез» дип кенә җавап бирәләр.

Хәзер Татар Караболагы башында көн-төн милиция тора, авылга беркемне рөхсәтсез кертмиләр дә, чыгармыйлар да. Коелар күмелде, елгага юл ябылды, инде чират иген кырларына да җитте. Чиләбе өлкәсе башкарма комитеты карары белән, Татар Караболагы авылының 3995 гектар җирләре, моннан тыш 3217 гектар авыл хуҗалыгы җирләре, 2374 гектар сөрү җирләре, 727 гектар печәнлекләр, 29 гектар көтүлекләр, радиация белән агулану сәбәпле, файдаланудан алына, ягъни халыкка бу җирләрдән файдалану тыела. Караболак авылы кергән «Жданов» колхозы бөтенләй бетерелә. Чиләбедә Караболакны күчерергә дигән катгый карарга киләләр.

1959 елның 29 сентябрендә, «Маяк»тагы атом шартлавыннан соң нәкъ ике ел үткәч, Чиләбе өлкә башкарма комитетында яшерен бер документка кул куела.

546 нчы номерлы бу карар радиациядән көчле зарар күргән Татар Караболагы авылын башка урынга — өлкәнең Әшир, Тахталым авылларына күчерү турында була. Бу күчерүнең җитмеш сигез миллионга төшәчәге әйтелә.

Әмма атомчылар моның белән ризалашырга теләмиләр. Чөнки алар бу тирәдә яшәүче бөтен халыкның да шулай кузгалуыннан, күчеп китәргә теләүләреннән куркалар. Алар уйлавынча, бу, беренчедән, атом белән бәйле дәүләт серенең

таралуына китерергә мөмкин икән, икенчедән, «Маяк»тан зур чыгымнар сорый. Өченчедән, «Маяк»тагы очсызлы эшче көчләр читкә тарала. Дүртенчедән... Монысын инде бары тик Ткаченколарның яшерен оешмалары, шушы оешмаларга хезмәт итүче галимнәр генә белә.

Шулай итеп, авыл күчерелмичә кала. Мәскәүгә «Караболак күчерелде» дигән белешмә җибәрелә. Кайсы Караболак — урысымы, татарымы — моны беркем тикшереп, җентекләп тормый. Ул арада, бик сәер шартларда, авылда урта мәктәп һәм авыл советы янып китә. Битлек кигән нindiдер чит кешеләрнең, аларга ут төртеп, урманга кереп качуларын күреп калучылар була. Шулай итеп, колхоз юк, авыл советы, андагы бөтен документлар янган, мәктәп янган, балаларның исемлеге юк. Димәк, авыл үзе дә юк? Ягъни кешеләре бар, ә авыл үзе юк. Иртәштәге шартлаудан соң, Татар Караболагы нәкъ менә шундый сәер хәлдә кала — ул яшәп килгән авыллар исемлегеннән сызып ташлана. Карталардан алына. Урыс Караболагы белән бергә Татар Караболагы да күчерелгән дип исәпләнә башлый. Шулай итеп, совет хөкүмәте кәгазьләрендә ул юкка чыга. Татар Караболагы авылы тулысынча Ткаченколар командасы кулында кала. Бу татарлар аларга атом тәҗрибәсе үткәрү өчен кирәк булалар.

Гөлҗиһан кырык көн, кырык төн буе яшәү белән үлем арасында бәргәләнде...

Аның башындагы бөтен чәчләре коелып бетте, тәнендәге тиресе урыны-урыны белән кубып чыкты. Баланың авызборыныннан, хәтта колакларыннан шаулап кан китте, эче тотмады. Каршы йортта әтисенең энесе Хәбибулла нәкъ шундый хәлдә ята, ул инде бөтенләй кибеп-корып бетте. Күренеп тора — аларның икесендә дә бер үк авыру, әмма аның нинди чир икәнлеген берәү дә белми. Еллар үткәч, мондый авыруларга «нурланыш», ягъни «лучевая болезнь» дип диагноз куярлар, әмма илленче еллар ахырында кем белсен аны татар авылында? Район үзәге ерак, Чиләбе исә аннан да ары, үлсәң дә, калсаң да, белүче юк. Шуңа күрә бу зәхмәттән һәркем үзенчә котылырга тырыша, котыла алмаганнар кинәт кенә зиратка күчә. Авылның Караболак елгасы буендагы Сәкәлин дип аталган урамыннан әзмәвердәй ничә япьяшь ир-ат шулай тәгәрәп үлде инде. Бүген бар, иртәгә юк кеше, үлем сәбәбен белмичә дә калалар. Менә Гөлҗиһанның Хәбибулла әзие дә, атна-ун көндә үпкә-бавырларын косып, утыз яше дә тулмас борын күзгә карап үлеп китте. Иртәштәге яшь хатыны да, берсеннән-берсе кечкенә балалары да, шәһәр читендәге яңа салган өе дә — барысы да торып калды. Төпчек улларын төп йортта калыр дип өметләнеп яшәгән

карт ата-ана да утырып калды — әзмәвердәй ир бала китеп барды.

Нәбиуллаларның зур нәселендә бу беренче олы югалту, көтелмәгән фаҗигале үлем иде. Улының күзгә карап тилмереп үлүен Нурҗамал карчык бигрәк тә авыр кичерде. Ул ике йорт арасында — оныгы Гөлҗиһан белән улы Хәбибулла арасында бәргәләнде, аларны үзенчә карарга, коткарып калырга тырышты. Өшкерде дә, кот та койды, төрле үлән төнәтмәләре дә эчереп карады аларга Нурҗамал карчык, әмма зәхмәт каты ябышкан иде. Таһирҗан карт та аларга Биташ чишмәсе суын эчереп карады, тән яраларына зәңгәр балчыкны сөртте, әмма Хәбибулланың гомере беткән иде инде. Гөлҗиһан — яшь җан, үлем авызыннан үрмәләп диярлек чыкты, ә Хәбибулла бу газапларга түзә алмады — өзелде. Ул соңгы мизгеленә хәтле үлем белән тартышты, гел терелер кебек тоелды. Ярулла карт белән Нурҗамал карчык аның яныннан китмәделәр, бала караган кебек карадылар, аның өчен балалар кебек утырып еладылар. Ун баладан иң төпчеге, иң газизе, иң таза-савы менә шулай җан биреп ятсын әле.

Үләр алдыннан Хәбибулла аңына килде, янында тәһлил әйтеп торган ата-анасына, туганнарына карады. Аның аларга әйтәсе бик зур сере, сүзе бар иде, әмма теле аңа буйсынмады, авызыннан сүзләре чыкмады. Ул, газапланып, авыз эченнән генә нидер пышылдый, мыдырдый башлады. Аның ни әйткәнен ишетергә теләп, Таһирҗан карт якынрак иелде, колагын Хәбибулланың көйгән иреннәренә куйды. Ул: «Атом... Үлем...» — дип пышылдый иде.

— Шаһәдәт кәлимәсен әйт, энем, «Ләә иләһә иллаллаһ» дип әйт, — диде Таһирҗан карт, аның соңгы мизгелләре җиткәнен сизенеп.

Хәбибулла аңа тутырып бер карады, иреннәрен чак кыймылдатып, абыйсы артыннан «Ләә иләһә иллаллаһ» дип кабатлады да күзләрен йомды. Аның йөзе кинәт кенә тынычланып, йомшарып калды, ирен читләрендә зәгыйфь кенә елмаю күренде. Ул җирдәге газаплардан котылган иде.

Хәбибулланы юып, күмәргә алып чыгып киткәндә, Нурҗамал карчык җиңеләю хәленә килгән иде инде. Әле ярый килене Хәбирә аның яныннан чыгып тормады, үзе авыру булса да, авырыксынмыйча, ике йорт арасында бөтерелде. Ирләр Хәбибулланы күмәргә алып чыгып киткәч, берара Нурҗамал карчык ялгызы гына калды. Аның бернәрсәгә дә кулы бармады, ике рәкагать нәфел намазы укып алгач кына бераз тынычланган кебек булды. Карчыкның күз алдыннан бөтен гомере, ун баласы тезелеп үтте. Барысы да ир балалар, барысы да, Алып батыр кебек, гәүдәлеләр, тазалар, сәламәтләр, бөтен тирә-якка дан нәсел. Менә шул асыл гәрәбәсе өзе-

леп китте Нурҗамал карчыкның, әҗәл исәп-хисапны аның төпчегеннән башлады. Аларның нәселе ике яктан да туксанга, йөзгә хәтле яшиләр иде, мондый хәлне күргәне булмады аларның, инде башка күрергә дә язмасын, Раббым.

Шушы теләгенә ияреп, Нурҗамал карчыкның күңеленә берәм-берәм шигъри мөнәҗәт юллары килә башлады. Караболак авылында шундый бер гадәт бар — биредә халык, нинди кайгы килсә дә, бәет чыгара. Хәтта кеше үзе үлгәнче үк бәетен чыгарып калдыра, аннан соң аны бөтен туганнар, Караболак халкы елый-елый укый. Хәбибулла — өрлектәй ир, үзенең шулай тиз үләсенә ышанмады, бәет тә чыгармады. Аның хакында мөнәҗәт-бәетне соңыннан әнисе-карчык чыгарды. Менә ул, зират ягындагы тәрәзәгә карап, әле генә улы яткан караватбашында, ялгыз өйдә күңеленнән шул мөнәҗәтне әйтә. Бөтен йорт, урам, Караболак карт ананың хәсрәтен тыңлый, аның белән бергә кайгыра, елый. Балалары Караболак зиратына күчеп яткан барлык аналар аның белән бергә шушы мөнәҗәтне әйтәләр иде:

Тугыз ай күтәреп йөрдем,
Тугач та сөтемне бирдем.
Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран,
Баламның хәсрәтен күрдем.

Бишекләрдә тибрәткәндә,
Тала иде беләкләрем.
Сезләр тыныч булмасагыз,
Әрнер инде йөрәкләрем...

Бала дигән асыл агач
Ананың карынында ята.
Баланың канлы хәсрәте
Ананың йөзен саргайта.

Бәгырь балам, газиз балам,
Ике күземә бер кара.
Синең ялкыныңда янам,
Сабырлык бир, Раббым Алла...

Нурҗамал карчык ишектән килене Хәбирәнең килеп керүен дә сизмәде, зират ягына карап, үзәк өзгеч моң белән мөнәҗәт әйтүен дәвам итте. Аны ишеткәч, Хәбирә үксеп елап җибәрмәс өчен куллары белән авызын каплады, әкрен генә ишек янындагы урындыкка килеп утырды. Көзге эңгер иңә башлаган буш йортта карт ананың йөрәге телгә килеп сөйли иде:

Йөрәкләрне утлар алган,
Бәгырьләрне шулар ярган.
Бу хәсрәтнең ачылары
Рәсүлуллаһбыздан калган.

Исемен язып калдырдым
Яна торган яфракларга.
Түзмәенчә ни хәл итим
Үзең биргән хәсрәтләргә.

Анадан туа бер бала,
Дөнья утларында яна.
Шул утларда яна-яна,
Кара туфрак чорнап ала.

Хак Тәгалә хәсрәтенә
Үз рәхмәткәйләрен биргәй.
Һәр адәмнең язмышында
Ходаның тәкъдире бар кый.

Бу сүзләрне ишеткәч, Хәбирә түзә алмады, урындыкка капланып елап җибәрде. Аннан каенанасын килеп кочаклап алды, хәзер инде алар бергәләп елыйлар иде. Һәркем үзенекен уйлады, Нурҗамал карчык — кара җир куенына кереп яткан улын, Хәбирә — үлем белән көрәшеп яткан кызын. Алай да Хәбирәнең өмете бар иде — Гөлҗиһан бүген күзләрен ачты, кеше таный башлады, картнәен сорады.

— Гөлҗиһан күзен ачты, әнкәй, — диде ул, бераз тынычлангач. — Сине сорый, «Картнәй нигә керми?» ди.

Нурҗамал карчыкның сүнеп барган күзләренә җан кергән кебек булды, туңып барган йөрәге яңадан тибә башлады. Үз хәсрәте белән оныгы турында исеннән дә чыгарган бит, югыйсә ул да хәл эчендә бит инде, үлем белән көрәшеп ята.

— Сөйләшә башлады, дисеңме, килен?

— Әйе, әнкәй, бераз тавык шулпасы да йотты бүген.

— Әй, рәхмәт яугыры. Әйдә, килен, алып чык мине тизрәк Гөлҗиһан янына. Картнәен көтеп ята икән бит, сабыем.

Килен белән каенана, шушы шатлыклы хәбәрдән дә яңадан тугандай булып, Гөлҗиһан янына ашыктылар. Алар өчен яшәү мәгънәсе хәзер шушы бала иде.

Ничә көннәр ут эчендә кан косып яткан Гөлҗиһанны инде терелмәс дип уйлаганнар иде. Алар классыннан Урыс Караболагында эшләгән берничә бала шулай кисәк кенә үлеп киткәч, Гөлҗиһанның әнисе елый-елый кызы өчен кәфенлекләр әзерләп куйды. Шулай итеп, бер елда ике баласын күмәргә туры килерме икәнни? Кап-кара мазутка чорналып, үле туган баласын күмде бит инде ул бу җәй. Ул авырлы килеш кыш буе басуда төтенләп торган эскерт өсте төшереп йөрде, укшып, ак кар өстенә ауган вакытлары күп була иде аның. Яз җитүгә, мәҗбүриләп, Урыс Караболагына кудылар, авырлы дип тормадылар, мылтык астында чиркәү кирпечләре ташыттылар. Ул, борынына җиткән корсагына терәп, аларны машинага төяде, Гөлҗиһанга авыр булмасын дип, аның өлешен дә күтәрергә тырышты. Кирпечләр өстенә утыр-

ган аксыл тузан аның авыз-борынына, күкрәгенә тулды, укшытты һәм костырды. Аның радиация тузаны булганлыгын Хәбирә кырык елдан соң гына беләчәк. Эшли алмыйча кире чыккан саен, кораллы сакчылар аларны яңадан шунда кудылар. Үле бала табуының сәбәбен Хәбирә әнә шунда тончыга-тончыга эшләвеннән күрде. Балага Галия дип исем кушып, юып-кәфенләп күмделәр. Инде Хәбирә менә икенче баласына — олы кызы Гөлҗиһанга кәфенлек әзерләде. Бары тик Таһирҗан карт кына бу кайгыга бирешмәде, Гөлҗиһанның үләренә ышанмады, шул барысына да бераз көч-өмет бирде. Таһирҗан карт Гөлҗиһан яныннан китеп тормады, аңа бары тик Аллакүл чишмәсе суын гына өшкереп эчерде, шуның белән бит-кулларын, бөтен тәнен юдырды, тагы үзе генә белгән әллә нинди хикмәтләр, әллә нинди догалар кулланды. Ул Гөлҗиһанны теге дөньядан үз куллары белән тартып чыгарды, чөнки әле аның гомере бетмәгән иде...

Һәм Гөлҗиһан, барысын да таң калдырып, аңына килде һәм картнәен сорады. Бу — Хәбибулланың үлгән, Гөлҗиһанның яңадан яши башлаган көне иде. Кызы янында каенанасын калдырып, Хәбирә иренә шатлыклы хәбәр җиткерергә ашыкты. Башта үзе озаклап авырып ятып, аннан кызы, каененесе белән ике арада бәргәләнеп йөреп, Хәбирәнең шактыйдан Караболак урамнарына чыкканы юк иде. Ул, читәнгә сөялеп, җанга газиз бу күренешкә озак карап торды, яңадан тугандай, өзелеп, сагынып карады.

Хәбирә — ятим бала, аның ата-анасы егерме беренче елгы ачлыктан Галикәй авылында үлеп калганнар. Ул кечкенәдән Караболакта, ерак туганнарында тәрбияләнде, шуңа күрә Караболак аңа туган авылы кебек якын, кадерле. Ул шушында авылның иң матур, иң булган егетенә — Алып Ханнар нәселеннән Нәбиуллага — уналты яшеннән кияүгә чыкты, аны сигез ел армиядән, сугыштан көтеп алды. Беренче балалары туу белән үлде, Нәбиулла аны күрмичә дә калды. Икенче балалары Гөлҗиһан инде озак еллар үткәч, Нәбиулла сугышлардан исән-сау әйләнеп кайткач, кырык алтынчы елны гына туды. Һәм шуннан соң нигәдер, тагы озак еллар баласы булмады Хәбирәнең, бу елларда авылда да балалар аз туды, туганнары да гел чирләшкә була башлады. Моның сәбәбе — үзләреннән кырык чакрым ераклыкта эшли башлаган атом реакторлары икәнлеген авыл халкы әле башына да китерми иде. 1957 елгы шартлауга хәтле үк, Иртәштәге дистәләгән атом казаны ун ел буе йөз чакрымдагы бөтен тирә-якка үлем нуры тарата башлаган иде инде. Шартлау шушы кырылышның дәвамы гына булды. Әмма Караболак халкы болар турында кырык елдан соң гына дөресен белә

алды. Ул вакытта авыл халкы шушы атом нурыннан кырылып бетә язган иде инде...

Әле хәзергә кырык яше дә тулмаган Хәбирә, читәнгә сөялеп, Караболакка карап тора. Авыл, моңсу гына саргаеп, үзенең алтын көзенә кереп килә икән инде. Дөнья хәвеф-хәтәр белән тулы булса да, табигать барыбер үзенекен итә — вакытында җәе-көзе килә, вакытында кошлар кайта, үз вакытларында китеп тә баралар. Әнә Караболак өстеннән дә, тезелешеп, торналар китеп бара. Бакчаларда инде бәрәңге ала башлаганнар, яшелчә өлгергән, алмалар коелып, тәгәрәшеп ята. Исән кешенең яшисе бар, шуңа күрә беркем дә үлем көтеп ятмый. Караболак халкы, гомумән, дөньяга бераз өстен торып, фәлсәфи күзлектән карый, авызы тулы кан булса да, аны кешегә күрсәтми. Аларны аңламаган башка авыллар моның өчен караболаклыларны тәкәбберлектә гаеплиләр, имеш, әллә кем булып, борын күтәргән булалар. Ә Караболак халкына әллә кем булырга кирәкми, ул үзенең кемлеген бик яхшы белә, шуңа күрә, үлем бугазларына басканда да, сер бирмиләр, кеше кебек яшәп калырга тырышалар. Хәбирә үзе дә хәзер алар кебеккә әйләнеп бетте инде, шуңа күрә Караболак турында беркемнән дә начар сүз әйттерәсе килми.

Ире Нәбиулла каршына елга буйлап кына барырга булды Хәбирә. Яр буйлап сузылган тимерчыбыкларны күреп, ул тагы сискәнеп китте. Куркыныч, ямьсез иде бу күренеш, Караболак өчен бөтенләй чит-ят иде. Әмма халык аңа бик игътибар итми, күрәсең, кем кайдан теләсә, шуннан йөреп торалар, суын алалар, балыгын тоталар. Ә балык һичкайчан булмаганча күп хәзер Караболак суында, авыл халкының мондый хәлне әле беркайчан да күргәне юк иде. Алар бүрәнәдәй озын, симез, итләре ашап туйгысыз. Әмма Караболак халкының элек-электән балыкка артык исе китмәде, ул ит белән яшәп өйрәнгән халык, шуңа күрә балыкны да читтән кайткан яшьләр генә тота. Хәбирә күреп калды, әнә хәзер дә яр буенда балык тотып йөрүчеләр бар, барысы да кайткан халыкка охшаган. Кызыксынып, Хәбирә ярга якынрак килде һәм имәнеч хәлне күреп, чак кычкырып җибәрмәде. Бу кешеләр тотып чыккан балыклар дөм сукыр һәм аларның тәннәре тишкәләнеп беткән, хәтта үлекләп тора иде. Хәбирә шул чакта су буендагы кешеләрнең дә битлектән һәм ак халатлардан икәнлеген күреп алды һәм тизрәк ярга үрмәләде. Бу чирле балыкларны читтән килгән белгечләрнең тикшереп, җыеп йөргәннәрен аңлады ул.

Зират ягыннан кайтып килгән ирен Хәбирә әнә шул хәлдә каршы алды. Ул аңа башта Гөлҗиһанның терелүен хәбәр итте, аннан Караболак ярында күргәннәрен сөйләп бирде. Нәбиулла бу хакта белә икән инде, авыл халкы да тәннәре

тишек бу сукыр балыкларны күргәннәр, хәзер беркем елгага якын бармый. Кемнәрдер авыл башындагы Бугай сазлыгыннан эт башы зурлыгындагы бакалар да күреп кайтканнар, алар эт өргән тавыш чыгарып кычкыралар икән. Кемдер бу көзне урманда кеше башы зурлыгы гөмбә тапкан, кемдер ике башлы төлке күргән. Үз гомерендә мондый хәлне күрмәгән-белмәгән Караболак халкы чын мәгънәсендә шомлана калды, су буена төшмәс, урманга кермәс булды.

Шулай итеп, атом шартлавы астында калган татар авылы үзенең фаҗигале яңа тарихын башлады.

Инде аларны каядыр күчерү турында беркем сүз кузгатмый, киресенчә, бөтен чәчүлек, көтүлек җирләрен яңадан аларның үзләренә кайтарып биргәннәр иде. Мең елга җитәрлек радиация белән агуланган җирләрдә халык яңадан иген игә башлады, малын йөртте, яшелчә-бәрәңгесен үстерде. Ә алар котырып үсте, гомер күрелмәгән уңыш бирде, Караболак халкы иген-икмәген, яшелчә-бәрәңгесен кая куярга белмәде. Чөнки Караболак кырларында үскән игенне, яшелчәне беркая да кабул итмәскә дигән яшерен әмер бар иде. Караболак халкына хәтта абзардагы тиресне дә авылдан читкә чыгарырга ярамый иде. Аларны күршедәге урыс совхозы «Кояш»ка кушып куйдылар һәм тынычлыкта калдырдылар. Кәгазьләрдә күчерелгән, гамәлдә үз урынында утырып калган Татар Караболагы авылы яшәү өчен көрәшнең яңа чорын башлады.

## Уникенче бүлек

Иртәштәге атом комбинаты, 1957 елда зур җимерелүләр һәм фаҗигаләр кичерсә дә, эшләвеннән бер минутка да туктамады, киресенчә, җир астына һәм җир өстенә дистәләгән чакрымнарга җәелә барып, тирә-юньне басып китте. Шәһәр һәм бу тирәдә яшәүче халыкның зур күләмдә радиация алганлыклары билгеле булса да, аларны урыннарыннан кузгатмаска булдылар. Моның үзенә күрә җитди сәбәпләре дә бар иде. Мәскәүдәгеләрнең фикеренчә, СССР, зур көчләр куеп, атом бомбасы ясауга иреште, бу хакта бөтен дөньяга белдерде. Казахстан һәм Ырынбур далаларында, көньякта һәм төньякта бу яңа үлем коралына сынаулар уздырыла башлады, күпме чыгымнар тотып, ракеталар һәм атом су асты көймәләре эшләнеп ята. Боларның һәммәсенә дә «Маяк» кирәк, анда җитештерелгән плутоний кирәк, шуннан башка болар барысы да коры уенчык кына. «Маяк»ны япкан очракта, боларның берсе дә булмаячак, чөнки яңа урында мондый атом комбинаты төзү өчен озак еллар кирәк булачак. Атом шартлавыннан соң халыкны кузгатмауларының икенче сә-

бәбе — бу серне дөньяга чыгармау. Ягъни Иртәштә ни ясалганын да, ни булганын да дөньяның бер генә иле, бер генә кешесе дә белергә тиеш түгел, «Маяк» белән бәйле бөтен нәрсә — ул дәүләт сере. Шуңа күрә, галимнәрнең һәм өлкә җитәкчеләренең кат-кат кисәтүләренә карамастан, «Маяк»тагылар, Мәскәү белән киңәшеп, радиация астында калган татар авылларын урыннарыннан кузгатмаска, күчермәскә булдылар.

Ул арада «Маяк»та тагы бер радиохимия заводы сафка басты, радиоактив калдыклар эшкәртү цехлары төзелә башлады, яңа атом реакторларына нигез салынды. «Маяк» куәтләнгән саен, тирә-якка атом калдыклары ташлау да арта, чөнки аны башта кая куярга да белмиләр, елга-суларга агызып баралар. Аннан атом калдыкларын ташлау өчен комбинат тирәсендәге Карачай күлен файдалана башлыйлар, ул да тулгач, бу агуны Кызылташ, Олыагач күлләренә, Теча, Мәшәләк елгаларына, Метлино буасына, сазлыкларга ташлый башлыйлар. Җир астыннан һәм җир өстеннән бу сулар бөтен тирә-якка тарала, Караболактан — Сәнәргә, аннан — Исәткә, алар аша Иртыш-Тубыл-Обь елгаларына чыгып, «Маяк»ның атом калдыклары Төньяк Боз океанына килеп җитә. Мең чакрым арада бу суларны файдаланган тагы меңләгән кеше көчле радиация ала, рак белән чирли башлый. Көньяктан исә атом калдыклары җир асты суларына кушылып, Чиләбегә таба хәрәкәт итеп ята. Көтелмәгән урыннарда җир өстенә бәреп чыгып, алар күлләрне корыталар, мал-туарны кырып салалар, кешеләргә мәңгелек атом тамгасы салып китәләр.

1957 елдан соң да «Маяк»та төрле аварияләр, шартлаулар гел булып тора, әмма аны халыктан бик нык яшерәләр. 1958 елның 2 октябрендә комбинатның егерменче номерлы заводында уран белән бәйле тәҗрибә уздырганда, көтмәгәндә зур авария була, анда эшләүчеләр көчле радиация алалар. Нәтиҗәдә күп кеше үлә, сукыраючылар, гарип калучылар була. Ткаченко командасы бу серне халыкка чыгармас өчен барысын да эшли, больницаларга рак диагнозын куймаска дигән катгый әмер килә. «Маяк»та мондый аварияләр елга берничә булып тора, йә реакторларга су килми башлый, йә, торба тишелеп, радиоактив калдыклар агып ята, йә завод торбаларыннан һавага чамадан тыш радиация тарала. Беренче елларны атом комбинатында саклык чаралары булмый, алар аны белми дә. Коры кул белән уранда казынып, плутонийны чиләкләп ташып, Советлар Союзы үзенең атом бомбасын ясауга ирешә. Әмма бу юлда ул меңләгән урынсыз корбаннар бирә, бу ил өчен атом адәмнән кадерлерәк булып чыга.

Ә тирә-юньдә татарларның күпләп үлүен аларның үзләренә кайтарып калдыралар. Имеш, татарлар начар туклана, туганнар белән өйләнешеп, кан катнаштыра, шуңа күрә алар күпләп үләләр икән. Бу якларда моңа кадәр күпчелек татарларның йөзгә хәтле яшәвен, алыптай гәүдәле, тимердәй бәдәнле булуларын, үзләреннән соң дистәләгән бала, йөзләгән онык калдыруларын атом коралын ясаучы урыслар белми дә, белергә дә теләми. Чөнки Ткаченколар командасы өчен бу татарлар — бушлай эш аты, әзер тәҗрибә тычканы булара кына кирәк.

«Радиацияне бетерә» дигән сылтау белән, «Маяк» тирәсендәге татар авылларына күпләп очсызлы аракы кертеп тутыра башлыйлар. Эчүнең ни икәнен белмәгән мөселман-татар халкы өстенә тагы бер иблис ябырыла. Каты сызлануларга түзә алмыйча, күпләр аракыны наркотик урынына куллана башлый, эчкәч алар авыруларын да, тормыш авырлыкларын да беразга онытып торалар. Шулай итеп, радиациягә ияреп, Урал артындагы татар авылларына аракы килә, рак килә, үлем килә. Моның җирле халыкка каршы Мәскәү тарафыннан уздырылган махсус мәкерле сәясәт икәнлеген татарлар бик соңга калып аңлыйлар.

...Быелгы табигать Караболак халкын аптырашта калдырды.

Уралда табигать болай да көйсез, әмма быелгы кебек хәлләрне Караболакта күптән хәтерләмиләр. Башта кыш буе буран котырды, авыл юлларын, урамнарны тирән көрт басты, аякланып йөрерлек хәл калмады. Инде җепшетә башлагач, февраль уртасында коеп яңгыр ява башлады, Уралтау өстендә яшен яшьнәп күк күкрәде, күңелләргә шом салып, аҗаган уйнап торды. Аннан тагы туңдырып җибәрде, өшеткеч салкыннар китереп бәрде, яңгырдан ачыла башлаган тау битләрен боз каплады. Бу дөньяда инде барысын да күргән Караболак халкы сабыр гына табигатьнең үз көенә керүен көтте, чөнки, ни генә булса да, кыш артыннан барыбер яз киләчәк иде. Ә яздан соң ямьле җәй башланачак. Караболак халкы әнә шул гап-гади тормыш фәлсәфәсе белән яши иде.

Быел да шулай булды, әмма җәй вакытыннан иртә килде, июнь башында эсселек инде утыз градуска җитте. Бу исә корылык киләсенә шомлы хәбәр иде. Әмма авыл халкы моңа да алып бәрелмәде, үз көе белән яшәвен дәвам итте. Караболак халкы өчен бүген иң мөһиме — туган туфракта калу иде. Күпме сөйләнсәләр дә, аларны бер җиргә дә күчермәделәр, кырларны яңадан үзләренә кайтарып бирделәр, елгадан файдаланырга рөхсәт иттеләр. Кыскасы, Караболакны үз урынында калдырдылар. Начаргамы бу хәл, яхшыгамы —

монысын беркем дә белми, әмма тормыш дәвам итә һәм кешеләр шунысына да шат иделәр. Дөрес, авылда чирләүчеләр күп, кинәт үлемнәр күп, әмма моның чын сәбәбен халык белми һәм һәркем бу хәлдән үзенчә чыгарга тырыша. Быел да менә, җәйгә керү белән, карт-карчыклар төрле үләннәр, тамырлар, бөреләр җыеп киптерә башладылар, яшьләр бакча тутырып яшелчә-җимеш утырттты, умарта тотты, мал-туар үрчетте. Авыл халкы, инде тынычлана төшеп, тагы үз җаена яши башлады.

Гөлҗиһан да быел ундүртенче җәе белән бара. Теге вакытта үлем тырнагыннан тырмашып исән калгач, ул тиз аякка басты, яңадан тернәкләнеп, терелеп китте. Нурҗамал картнәе белән Таһирҗан бабасы аны аякка бастыру өчен нәрсә генә эшләмәделәр! Ул өшкерүләр, ул әллә нинди төнәтмәләр эчерүләр, ул кан агызулар, сөлек салулар, кара мунчага алып кереп кот койдырулар. Берсе дә калмады. Ашауны да Гөлҗиһан өчен аерым тоттылар, әтисе аңа ризыкны хәтта Урал аръягына хәтле барып алып кайта иде.

Ә Таһирҗан бабай өшкереп биргән Биташ чишмәсенең суы... Ул аны тау куышының эченә үк кереп, иң чиста җиреннән ала торган булган. Гөлҗиһан бары тик шуны гына эчте, шуның белән генә юынды, башка суга борылып та карый алмас булды. Ул суны эчкәч, Гөлҗиһанның бөтен күзәнәкләре ачылып, дөньясы яктырып китә иде, кыз бала үзендә моңа кадәр булмаган көч, җиңеллек, рәхәтлек тоя. Әйтерсең лә аның иңнәренә канатлар үскән һәм алар аны Караболак өстеннән очырып йөртәләр. Дөньяда тере суы була торган булса, ул, мөгаен, шушы Биташ чишмәсе суыдыр. Таһирҗан карттан күреп, һәм Гөлҗиһанның шуны эчеп савыкканын белеп, Караболак халкы да суга шул чишмәгә йөри башлады. Һәм, ни хикмәт, авырулар шактый кимеде, кешеләр яңадан аякка бастылар.

Караболак, җан тырмашып, исән калу юлларын эзли иде.

Яшьләр гашыйк була, өйләнә, балалар үстерә, картлар аларга киңәш биреп, өйрәтеп тора. Җәй артыннан көз җитә, аннан карлы-буранлы кышы башлана. Караболак халкы, элек ничек яшәсә, шулай көн күрүен дәвам итә, әйтерсең лә кайчан гына авыл тулып хәрбиләр йөрмәгән, күчерәләр икән дигән шомлы хәбәрләр таралмаган. Әйтерсең лә әле кичә генә алар, үлем көтеп, өйләрендә тәгәрәшеп ятмаганнар, урам-урам зиратка күчмәгәннәр, билгесез авырудан кырылмаганнар. Әмма тормыш дигәнең шундый инде ул, бер кечкенә генә шатлык килдеме, кайгы онытыла, хәл бераз яхшырып китсә, авырлыклар истән чыга. Моның шулай булуы яхшыдыр, мөгаен, югыйсә адәм баласы гел кара кайгы эчендә генә яши алмый бит, ул барыбер тормышында бер якты нур табарга тырыша. Һәм табалар да.

Гөлҗиһан белән дә шулай булды. Ул бик тиз савыкты, тернәкләнде, яңадан чаяланып, шаянланып китте. Әйтерсең лә ул кичә генә кан косып ятмаган, әйтерсең лә аңа инде акбүздән кәфенлекләр әзерләп куелмаган булган. Хәзер әнә аны танырлык та түгел, кинәт кенә үсеп, тулышып китте. Аңа беркем ундүрт яшь бирми, ул инде буй җиткән яшь кызны хәтерләтә. Үзе шулхәтле тере, үткен, үзе, яшь тай кебек, беркемне якын җибәрми, тибенергә генә тора. Өйнең түрендә — ут борчасы Гөлҗиһан, урамда хуҗа — атамандай Гөлҗиһан, мәктәп түрендә — бишкә генә укучы Гөлҗиһан, клубта — иң матур кыз Гөлҗиһан... Үзе матур, үзе үткен, үзе башлы, үзе батыр, үзен барысы да ярата тагы. Кыскасы, Караболакта дөнья тагы Гөлҗиһан тирәсендә әйләнә башлады. Һәм бу аңа килешеп тә тора иде.

Авылда карап торган бер кыз булса да, Гөлҗиһан иркәләнеп өй түрендә утырмый, нәрсәгә тотынса, кулыннан шул килә аның. Ул беркайчан да эш кушканнарын көтми, аны Гөлҗиһан үзе таба, үзе ерып чыга, үз дөньясын үзе әйләндерә. Шуңа күрә Гөлҗиһанны авылда барысы да ярата. «Кем бәхетенә үсә икән Нәбинең бу кызы?» — дип сокланып аны күзәтәләр. Ә аның насыйбы бөтенләй башка җирдә яши, Гөлҗиһанның күптән инде аны күргәне юк. Ә күрәсе бик килә. Теге вакытта, Иртәштә шартлау булган көзне, ул атасы белән Караболакка кайткан иде. Ул шаян Гөлҗиһаннан күзен алмады, ә кыз, балалыгы белән, бөтен нәрсәне уенга борды. Аннан каты авыру барысын да басып китте, күрше егете Фәргать тә аксыл томан артына китеп югалды. Тиздән аны күрәсен, тәкъдирдә аларның язмышлары бергә бәйләнгән булуын да белми әле Гөлҗиһан. Аның язмышы әнә инде Караболакка якынаеп килә, тик үз хәсрәте, үз кайгысы белән кайта ул туган авылына. Бу хакта да әле Караболакта беркем дә белми.

Ул көнне кичкә таба көн кисәк кенә суыта башлады. Башта Урал ягыннан күгелҗем-кара болытлар күренде, аннан боздай салкын җил исә башлады. Көтүдәге мал-туар, хәвеф килгәнен сизгәндәй, авыл ягына карап чабарга тотынды, тизрәк ышык абзар-кураларга кереп качты. Көчәйгәннән-көчәя барган җил-давыл кош-кортны да кетәклекләргә куып кертте, ишек-тәрәзәләрне, ачык капкаларны шапылдатып йөри башлады. Караболакка төнгә таба көчле давыл килгәнлеге күренеп тора иде.

Шулчак Гөлҗиһаннар капка төбенә бөркәүле йөк машинасы килеп туктады. Гөлҗиһан тәрәзәдән күреп калды — машинадан солдат киемендәге яшь бер егет сикереп төште. Абзарда мал-туар янында йөргән әти-әнисе каршы алмагач, Гөлҗиһан, уктай атылып, машина янына үзе йөгереп чыкты.

Йөгереп чыкты да, каршында басып торган гүзәл егетне күреп, уңайсызланып, ток суккандай артка чигенде. Аның каршында элеккеге күршеләре Якупның улы Фәргать басып тора иде.

Моннан берничә ел элек, теге шартлау булган көзне, алар әтисе белән Караболакка кайтканнар иде. Якуп төрмә срогын тутырып кайткан һәм аның авылга күчәсе килә, алар бу хакта Гөлҗиһанның әтисе белән килешеп тә беткәннәр иде инде. Ул арада Караболакның үз язмышы да кыл өстендә калды, күчерәләр икән дигән сүз таралды. Аннан Якупның кинәт кенә авырып китүе турында хәбәр килде. Шуннан соң ара-хәбәрләр өзелеп торды, чөнки һәркемнең үз хәле хәл иде, һәр йортта авыру, һәр йортта мәет, кеше кайгысы калмады. Һәм менә шул күрше Якупның улы Фәргать хәзер солдат киемендә Гөлҗиһан каршында басып тора. Әмма никтер элеккеге кебек Гөлҗиһан белән шаярмый да, уйнамый да, хәтта аңа карап елмаймый да. Нигә шулай үзгәргән икән ул? Әллә берәр кайгысы бармы икән?

Гөлҗиһан, күңеле нидер сизгәндәй, каплаулы йөк машинасы ягына карады. Аннан елап шешенеп беткән балалар һәм Якупның хатыны күренде. «Ә Якуп әзи үзе кайда икән соң, нигә аннан башка гына кайткан алар?» — дип уйлады Гөлҗиһан, тирә-ягына карап. Аннан, җавап көткәндәй, зур яшькелт күзләрен Фәргатькә төбәде, тик, яшен суккандай, карашын тизрәк читкә борды. Ул Фәргатьнең моң, кайгы-хәсрәт, тагы әллә нинди хисләр белән тулы карашын күтәрә алмады. Бу караштан аның бөтен тәне эсселе-суыклы булып китте. Ул каршында басып торган егетнең аның өчен гади кеше генә булмыйча, язмышына үтеп керәчәк ир-ат буласын күңеле белән сизенә, шуңа күрә каушый иде. Бәхетенә, Гөлҗиһанга ярдәмгә өйдән әтисе килеп чыкты. Ул Фәргатькә һәм машинага күтәрелеп карау белән нидер сизенде, егетне үзенең киң күкрәгенә кысты.

— Әтине алып кайттык, Нәби абый, — диде Фәргать. — Бөтенләйгә алып кайттык, күмәргә.

Ул арада башкалар да якынрак килделәр, өйдән Гөлҗиһанның әнисе йөгереп чыкты, каршы яктан ашыгып атлаган әби-бабасы күренде. Тирә-як халкы Гөлҗиһаннар капка төбенә җыела башлады. Якупның үлүе турында хәбәр бөтен авылга таралып өлгергән иде инде.

Якупның гәүдәсен үзенең ярым җимерек өенә куйдылар. Соңгы теләге шул булган икән — үз нигезендә соңгы төнне чыгу һәм Караболак зиратына күмелү. Сугыштан да, әсирлектән дә, төрмәдән дә исән кайткан әзмәвердәй Якуп, илле җиденең көзендә Караболакка килеп киткәннән соң, аяксыз кала, урын өстенә ята. Миасс — авыл җире түгел, больница-

дан больницага тикшерелә торгач, анда нурланыш авыруы табалар. Бура кебек ирнең бөтен тәне радиация белән агуланган булып чыга. Ул күз алдында кибә-корый башлый, бөтенләй аяк-кулсыз кала, тәнендәге һәр тишектән кан бәреп чыга. Иртәштә солдат хезмәте үткән Фәргатьне ашыгыч чакыртып кайтаралар, ата кеше аңа үзенең соңгы васыятен әйтеп калдыра. Васыяте — Караболак була, үлгәч булса да, ул шунда кайтып ятарга тели. Хатынының, сабый игезәк кызларының, улы Фәргатьнең күзенә карап, туган авылыннан еракта, Урал таулары арасында җан бирә күрше Якуп. Һәм менә үзенең ярым җимерек өендә ул бүген үзенең соңгы төнен чыга... Сугыш кырларында ятканда, немец әсирлегендә интеккәндә, Себер төрмәләрендә газап чиккәндә, ул шушы нигезе, Караболак авылы белән хыялланган, саташкан иде. Һәм менә хәзер бөтенләйгә кайтты. Кырык яшендә җир куенына кереп яту өчен, ул инде бөтенләйгә Караболакка кайтты. Аңа хәзер сугыш та, сөрелүләр дә, атом үзе дә куркыныч түгел — ул мәңгелек тынычлыгын туган авылында тапты. Үлгәч кайтып егылу өчен дә кешеләргә Караболак кирәк иде, туган авыл кирәк иде.

Ул төнне Караболак кыямәт көнен хәтерләтте.

Көндез түзә алмаслык эсселек булды, кичкә кинәт кенә суытып җибәрде һәм төнгә каршы авыл өстендә давыл купты. Бу — моңа кадәр адәм заты күрмәгән җил-давыл иде. Ул, котырынып, өй түбәләрен алып бәрде, йөзьяшәр агачларны төбе-тамыры белән куптарып ташлады, яшьрәк куакларны шартлатып урталай сындырды. Күктән авыл өстенә кар катыш балчык, агач кисәкләре, таш, тагы әллә нәрсәләр яуды. Якупның мәетен төн сакларга җыенган халык, куркышып, Гөлҗиһаннарга кереп тулды, таң атканчы беркем керфек какмады.

Иртә белән исә аларны тагы да тетрәндергеч хәлләр көтә иде. Кичә генә тузан тузгып торган авыл урамнарын тездән кар күмеп киткән, әмма ул кар ак түгел, кан кебек кып-кызыл, балчык белән катнаш иде. Моны күреп картлар: «Ахырзаман, ахырзаман!» — дип елаша башладылар, яшьләр дә өркеп калды. Кичә генә ямь-яшел булып утырган Караболак кызыл кар астында калган иде. Ярты авылның йорт түбәсе юк, күп кешеләрнең капка-коймалары ауган, абзарлар җимерелгән, куркынган мал-туар тездән кар эчендә басып тора. Иртәнге якта инде авыл өстендәге кара болыт таралган, Урал таулары ягына китеп ята иде, күк йөзенә, бу хәлләрдән оялып кына, кояш чыгып килгәнлеге күренде.

Әмма таш яуса да, йоласына туры китереп, мәетне күмәргә кирәк иде, ул үзенең түбәсез җимерек өендә соңгы юлга озатканнарын көтеп ята. Авыл ирләре беренче эш итеп зи-

ратка юлны чистарттылар, берничә кеше, ломнар белән чокып, кабер казырга тотынды. Әле җирнең өсте генә катып киткән, аста барыбер йомшак, көрәк керерлек иде. Таһирҗан карт исә, бөтен тәртибен китереп, мәетне юарга әзерли башлады. Хатын-кыз, бала-чага исә йорт тирәсен тәртипкә китерергә тотынды, чөнки эссе кояш астында кар эреп, бөтен җимерек, чүп-чар өскә чыккан, таралып ята. Гөлҗиһан да ишегалдында бөтерелеп йөрде, бу сылу кызның кулында ут уйнап тора иде, ул кагылган җирдә гөлләр яңадан баш күтәрде, чирәм чәчәк атты, алдында кошлар җырлап торды. Ә бәлки, Гөлҗиһанның җаны шулай кош булып сайрыйдыр, аның нурлы карашыннан гөлләр үсәләрдер, дөнья яшәрәдер? Дөнья өстенә таш яуса да, хәтта кызыл кар яуса да, ул бит үсмер кыз бала. Дөньяга гөлләр кебек шатланып үсәр өчен туган кыз бала, ярату-яратылу өчен туган кыз бала. Һәм шушы хисләр аңа бүген канат куйган, шуңа күрә ул ишегалды буйлап очып кына йөри.

Мәетне күмеп кайтканда, кар эреп беткән, табигать яңадан үз хәленә кайткан, авыл тагы үзенчә яши башлаган иде инде. Чөнки Урал аръягында, Караболак тирәләрендә мондый гарасатлар, җил-давыллар еш була, халык аңа инде ияләнгән иде. Бу юлы да соңлап кына булса да, көтү кудылар, җимерек читән-капкаларны утыртып куйдылар, таралып яткан түбә такталарын җыя башладылар. Халык мәеткә дә ияләнеп бара инде, биредә хәзер кеше күммәгән көн юк. Якуп кебек, үлгәч Караболак зиратына ераклардан кайтып ятучылар да бар. Аны күмәргә монда алып кайтуларын авыл халкы дөрес дип тапты, чөнки алар өчен Якуп барыбер Караболак кешесе булып калды. Гаиләсен, балаларын да шулай кабул иттеләр, аларны һәркем үзләренә алдырырга тырышты.

Гөлҗиһаннар өендә дә табын әзерләнә, чөнки ерак юлдан кайткан күршеләрнең аларда туктыйсы килде. Озата кайткан машиналарын бер генә көнгә биргәннәр, шуңа күрә, чәйләр эчеп алгач, кире китәргә ниятләделәр. Чәй янына Таһирҗан картны да дәштеләр, каршы яктан Гөлҗиһанның әбибабасы да кереп җитте, туганнар җыелышты. Якупның гаиләсен шулай итеп булса да олылыйсылары, кадер-хөрмәт күрсәтәселәре килде аларның. Гөлҗиһан исә мич белән өстәл арасында бөтерелеп йөрде.

— Урыны җәннәттә булсын Якуп күршенең, — дип сүз башлады Нәбиулла, йорт хуҗасы буларак. — Мин аңа гомерем белән бурычлы — ул булмаса, сугыш кырында ятып кала идем мин. Мине коткарам дип, үзе әсиргә төште. Соңыннан да шуның газабын күрде. Урыны җәннәттә булсын, инде анда булса да, газап күрмәсен...

Ике як та бу тарихны белә иде, әмма бүген ул бигрәк тә

тетрәндергеч булып яңгырады. «Күрше хакы — Тәңре хакы» ди Караболак халкы, Якуп ахыргача шушы изге әманәткә тугры булып калды. Нәбиулла исә күршесенә соңыннан булса да тиешенчә ярдәм итә алмавына уфтанды. Караболакка кайтып урнашырга өлгерә алмады бит күршесе, үлем аннан өлгеррәк булып чыкты.

Аның уйларын сизгәндәй, Фәргать әтисенең әманәтен әйтеп калырга ашыкты:

— Әти гомер буе Караболакка кайтам дип яшәде, — диде ул. — Үләр алдыннан безгә дә шуны васыять итеп әйтеп калдырды. Инде ни эшләргә дә белгән юк. Минем әле армия хезмәте бетмәгән, сеңелкәшләр кечкенә. Ничек кубарылып чыгып китәргә, кайда кайтып керергә?

Бу сүзләрне ишеткәч, Гөлҗиһанның йөрәге рәхәт кысылып, сулкылдап куйды. Әгәр Фәргатьләр Караболакка кайтсалар, Гөлҗиһан аны көн дә күрә ала бит, юк, сәгать саен, минут саен күрә ала! Бу уеннан Гөлҗиһан кызарып чыкты, ут булып янган бит алмаларын күрмәсеннәр өчен, тизрәк чаршау артына чумды. Әмма инде чуалып ташланган уйлары аңа монда да ирек бирмәде, төрле яктан килеп, Гөлҗиһанның яшь күңеленә үрмәләделәр. Гөлҗиһанның гомерендә әле мондый хәлнең булганы юк иде, аның дөньяда әле беркем турында да шулай өзелеп уйлаганы, уйланганы юк иде. Чәчәкле чаршауның теге ягында гына утырган солдат киемле күрше егет аның күңеленә кереп урнашкан иде инде. Менә ул, әле ерак балачакта, кечкенә Гөлҗиһанны кулларына күтәреп йөртә. Менә аларны, коры арбага утыртып, авылдан сөрәләр. Менә ул әтисе белән Караболакка нигез урыннарын карарга кайта һәм шаян Гөлҗиһаннан күзләрен алмый. Ул Гөлҗиһанның төшләренә керә, гел аның белән янәшә яши, аның өчен яши. Бәлки, бу күрше егет Гөлҗиһанның тәкъдиредер, бәлки, аның тормышыннан үтеп кенә баручыдыр. Бәлки, ул Гөлҗиһан турында уйламыйдыр да, чөнки аның өстендә хәзер тормыш йөге, ялгыз әнисе һәм кечкенә сеңелләре бит.

Шулчак чаршау артында Таһирҗан картның тавышы ишетелә:

— Өегезне бергәләп рәткә китерербез, кайтасы килсәгез, кайтыгыз, ылан, — ди ул.

Инде Фәргатьнең әнисе сүзгә кушыла:

— Алай гына кубарылып чыгып китеп булмас әле ул, — ди. — Менә Фәргать армиядән кайтсын әле, балалар бераз үсә төшсен. Анда бит әле авыру карт-карчык та бар, аларны кая куясың.

Фәргатьнең әнисе бу авыл кешесе түгел, ул монда Урал артыннан килен булып төшкән, шуңа күрә Караболакка кайтырга бик үк атлыгып тормый, күрәсең. Игезәк кызлар әле

кечкенә, берни аңламыйлар, ә әби-бабай урын өстендә ята, ди. Димәк, соңгы сүзне Фәргать әйтәчәк, Караболакка кайту-кайтмау мәсьәләсен ул хәл итәчәк. Гөлҗиһан тын да алмыйча, Фәргатьнең ни әйтүен көтте.

— Армиядән кайткачка кала инде, Нәбиулла абый, — диде ул, ирләрчә нык итеп. — Әтинең васыятен үтәрбез, насыйп булса, нигезне яңартырбыз. Тик бераздан инде, солдаттан кайткач.

Гөлҗиһанның күзләренә яшь бәреп чыкты. Солдаттан кайткач! Әле кайчан була ул — солдаттан кайту? Бер елмы, икеме, әллә аннан да күбрәкме? Анда нәрсә булмас? Нигә хәзер үк Караболакта калмыйлар икән соң алар?

— Нигә хәзер үк Караболакта калмыйсыз, Фәргать абый? — дип сораганын Гөлҗиһан сизми дә калды.

Өстәл янындагылар барысы да аңа таба борылып карадылар. Кызның ике бите ялкынланып яна, зур күзләрен әллә яшь, әллә моң сарган, керфек очлары дерелдәп, тетрәп тора иде. Кыздагы сәер халәт, яшерен наз һәм моң егеткә дә күчкән, ахрысы, аның да битләре алланып чыкты, күзләрен ул тизрәк читкә борды. Гөлҗиһанга туры карарга ул оялды, тирә-юньдәгеләр аның күңел хисләрен аңларлар дип уңайсызланды.

Өлкәннәр, яшьләрнең хәлен аңлагандай, сүзне җай гына башкага борып җибәрделәр. Яңа гына мәет күмеп кайтсалар да, барысының да күңелендә якты өмет сызылып үтте — тормыш дәвам итә бит әле, менә, яннарында яшьләр бар. Бер йортта — җитеп килгән кыз бала, икенчесендә — буй җиткән егет. Димәк, хыял бар, өмет бар, тормыш бар. Әмма Гөлҗиһан да, Фәргать тә үзләрендә җимергеч атом тамгаларын йөрткәннәрен белмиләр, чөнки алар әле артык яшь, артык куркусыз һәм артыгы белән бу тормышны яраталар. Иң мөһиме — алар хәзер бу дөньяда бер-берсе барын белә. Бер-берсенә кирәклекләрен күңелләре белән тоя алар. Шушы табигый хисләр, бәхеткә, мәхәббәткә омтылыш алдында калган барлык нәрсәләр вак булып күренә. Хәтта атом үзе дә.

Башта бер-берләренә вәгъдә итеп, бер сүз әйтешмәсәләр дә, ике арада хисләрдән күпер салынган иде инде. Һәм Гөлҗиһан өч ел буе Фәргатьне армиядән көтте. Бәхетенә, ул Иртәштә генә хезмәт итә иде, берничә тапкыр Караболакка ялга да кайтып китә алды. Шул кайтуларда ул Гөлҗиһанга үзенең хисләрен белдерде, әти-әнисеннән өйләнешергә рөхсәт бирүләрен сорады. Ата-ана, әби-баба, бөтен зур нәсел моңа сөенеп риза булды, күрше егетен тиң күреп, үз арасына алырга әзерләнде. Иртәш белән Караболак арасында көн саен мәхәббәт хатлары йөреп торды. Ата-ана, әби-баба, Кара-

болак халкы Фәргать белән Гөлҗиһанга ярәшелгән пар итеп карый иде инде. Авыл халкы алар өчен чын күңелдән куанды, чөнки Фәргать белән Гөлҗиһан, чыннан да, бик пар килгәннәр, тиңнәр иде. Икесе дә тәртипле, яхшы гаиләдән, икесе дә күз явын алырлык чибәр, икесе дә уңган-булган. Әле Караболакта яшәргә дә исәпләре бар икән. Һәм авыл халкы туй көнен көтеп яши башлады. Фәргатькә хезмәтен тутырырга нибары берничә ай калган иде. Гөлҗиһан мәктәпне тәмамлаган елны туй уздырырга килештеләр, шул көзне Фәргать хезмәтен төгәлләп кайтырга тиеш иде. Әмма ул көзен дә күренмәде, кышын, язын да үзе турында хәбәр бирмәде — Фәргать Иртәш суына төшкән кебек, кинәт кенә юкка чыкты. Гөлҗиһанга, әкияттәге ятим кыз кебек, җан сөйгәнен күрер өчен әле бик күп сынаулар үтәргә, авырлыклар кичерергә, зур юллар үтәргә туры киләчәк иде.

## Унөченче бүлек

Ерак Урал тауларында Фәргатьнең әтисе Якуп нурланыштан кибеп үлгән елны Мәскәүдә «атом атасы» Курчатов та көтмәгәндә үлеп китә.

Әле алтмыш яше дә тулмаган үгез кебек ирнең урам уртасында тәгәрәп үлүе күпләрне тетрәндерә, әмма кинәт үлемнең сәбәбен йөрәккә кайтарып калдыралар. Тик «атом атасы» академик Курчатов нурланыш авыруыннан үлә. Бөтен гомерен атом серләрен ачуга багышлаган, Иртәштән, «Маяк»тан кайтып кермәгән, үзе ясаган беренче атом бомбаларын сынауда катнашкан Игорь Васильевич Курчатов, атом корбанына әйләнеп, бер уч соры көл рәвешендә Кремль стеналарына кереп ята. Урал тауларында, гүзәл Сим буйларында туып үскән бу галим, гомеренең ахырында булса да, нинди куркыныч гыйфритне шешәдән чыгаруларын аңлый, әмма инде соң була... Утыз бер яшендә фән докторы, утыз ике яшендә күренекле профессор, СССРда уран проблемаларын өйрәнү буенча төп белгеч, өч тапкыр Социалистик Хезмәт Герое, дүрт тапкыр Сталин премиясе лауреаты, «Маяк» атом комбинатын, Обнинский атом электростанциясен, «Ленин» атомоходын төзүдә катнашкан «атом атасы» Курчатов 1960 елны Мәскәү урамында тәгәрәп җан бирә. Гомеренең ахырында булса да ул радиациядән тыныч тормышта меңләгән кешенең, хезмәттәшләренең гомере өзелүен күрә, алга таба атом коралы җитештерүне чикләргә чакырып карый. Әмма үлем тегермәне әйләнүен дәвам итә, атом аждаһасы инде җир астыннан чыккан була һәм ул яңадан-яңа корбаннар сорый. Сугыш өчен, СССРны саклау өчен дип төзелгән атом индустриясе илнең үз халкына каршы эшли башлый. Карабо-

лактан Якуп һәм «атом атасы» Курчатов бер чорда нурланыштан үләләр, радиация милләтләрне, сыйныфларны, дандәрәҗәне карап тормый — барысын да рәттән кыра. Бөтен ил өстендә атом аҗаганы уйный башлый, әмма аңа караган кешеләрне газаплы үлем көтә.

Иртәштә радиациядән иң күп кырылучылар уран һәм плутоний белән эш йөртүчеләр арасында була. Соңгысы бигрәк тә яшь хатын-кызларны кырып сала, чөнки плутоний белән эшләүчеләрнең күпчелеген яңа гына институт тәмамлаган кызлар тәшкил итә. Гаять куркыныч радиация белән эш йөрткәндә, бөтен саклык чараларын өс-баш алыштыруга һәм юынуга гына кайтарып калдыру аяныч нәтиҗәләргә китерә. Башта «Маяк»ның химия-металлургия заводы хезмәткәрләре, аннан радиохимия заводы эшчеләре һәм турыдан-туры реакторда эшләүчеләр кинәт кенә билгесез авырудан күпләп үлә башлыйлар. Кисәк хәлсезләнү, көчле баш авырту, йокысызлык, ашыйсы килмәү яки ашый алмау, күңел болгану билгеләре артында коточкыч нурланыш авыруы торуын һәм аның тиз арада үлемгә китерәсен әле ул вакытта күпләр белми. Плутоний белән эш итүчеләрнең кан составлары кинәт үзгәрә, үпкәләре, бавырлары, сөякләре череп таркала башлый. Алар бик нык ябыгалар, саргаеп кибәләр һәм тиз арада үлеп тә китәләр. Шулай итеп, 1950—1960 елларда «Маяк»та нурланыш авыруыннан утыз-утыз ике яшьлек күп кенә инженер-химиклар, лаборантлар үлә. Аларга әле кырык биш яшь тә булмый. Кайберләрен, аяк-кулларын кисеп ташлап булса да, алып калырга тырышалар. Әмма нурланыш һәм рак «Маяк»та инде тамыр җибәреп өлгергән була. Атом аждаһасын дөньяга чыгарып, биредә эшләүчеләр аны үзләре тудыралар.

Бу яман чир Иртәштә бик зур кешеләрнең дә башына җитә.

Аларны ток җибәргән биек таш коймалар да, адым саен куелган мылтыклы сакчылар да, хәтта Ткаченколар командасы да саклый алмый. Нурланыш һәм рак авырулары Иртәштә зур галимнәрне, дәүләт бүләге ияләрен, зур җитәкчеләрне чүпли башлый.

Плутоний буенча зур белгеч, академик, Ленин премиясе лауреаты, Дәүләт бүләге иясе, Социалистик Хезмәт Герое Александр Сергеевич Никифоров хроник нурланыштан үлеп китә. Шәһәр башкарма комитеты рәисе Николай Яковлевич Ермолаев, плутоний цехында эшләп, егерме алты яшеннән нурланыш авыруы ала, II группа инвалидка әйләнә һәм илле яшендә, үпкәләрен кистереп, куллары корып, каны бозылып үлә. Ленин ордены кавалеры, плутоний цехы җитәкчесе Евфалия Дембяновна Вандышева 1952 елда ук хроник

нурланыш белән авырый башлый һәм гомер буе газапланып, алтмышка җитмичә үлә. Ленин ордены кавалеры, химия цехы начальнигы Зинаида Алексеевна Исаеваны да шундый ук кара язмыш көтә. Ленин һәм Дәүләт премияләре лауреаты, 1957—1974 елларда «Маяк»ның директоры булып эшләгән Георгий Трофимович Залесский да шушы ук авырудан илле яшендә дөнья белән хушлаша. «Маяк»ка аннан соң килгән директор (1978—1988), Ленин һәм Дәүләт премияләре лауреаты Георгий Михайлович Нагорный да 1988 елда үпкә рагыннан үлә. «Маяк»ның соңгы җитәкчеләре дә кайсы баш мие рагыннан, кайсы үпкә рагыннан берәм-берәм үлә баралар.

Совет атом бомбасы үзен ясаучылар өстендә шартлый.

## Ундүртенче бүлек

Ул көзне Фәргать, армия срогын тутырып, өенә кайтырга тиеш иде.

Юк, Миасстагы ярым җимерек баракка түгел, Караболакка, атасы нигезенә кайтырга ниятләгән иде Фәргать. Әнисе, әби-бабасы, туганнары да моның белән килешкәннәр иде. Берничә тапкыр ялга кайтып, Фәргать инде йорт-җирне, абзар-кураны да рәтләп куйган иде. Аның Караболакка кайтырга теләвенең беренче сәбәбе — ата васыяте булса, икенчесе — күрше кызы Гөлҗиһан иде.

Гөлҗиһан...

Ул күзгә күренеп үсә, сылулана, гөл кебек ачыла бара. Караболакта гына түгел, бөтен тирә-якта аңа тиңнәр юк. Ул үткенлек, ул матурлык, ул әдәп-әхлак, ул булганлык — Гөлҗиһанда бар да ташып, нур чәчеп тора. Гадилеге белән бергә, ул үз дәрәҗәсен дә бик яхшы белә, патша кызы диярсең. Монысына Фәргать сөенә генә, чөнки Гөлҗиһан авылда беркемне үзенә якын җибәрми, егетләр аңа тырнак белән кагылырга да батырчылык итмиләр. Һәм менә шушы патша кызларына тиң гүзәл зат бары тик Фәргатьне генә ярата, аны гына көтә, киләчәген бары тик аның белән генә күрә. Үзенә насыйп булган мондый зур бәхеттән, кызның шулхәтле көчле саф мәхәббәтеннән Фәргать кайвакытта куркып та куя. Лаекмы соң ул мондый мәхәббәткә, Гөлҗиһан аны кызганып кына яратмыймы? Кыз каршында Фәргать артыгын сөйләргә дә, кыланырга да курка — горур, кыргый авыл баласын өркетеп, биздереп куюың бар. Ә Фәргатьнең Гөлҗиһанны бер дә югалтасы килми, ул үзенең тормышын, киләчәген бары тик аның белән генә күрә. Шуңа күрә солдат хезмәтеннән дә туп-туры Караболакка кайтырга уйлый. Бу көздә аларның

никах туйлары булачак, моңа Гөлҗиһан үзе дә, әти-әниләре дә риза. Шуңа күрә Фәргать солдат хезмәтенең һәр көнен, һәр сәгатен саный, аның әле моннан да озын җәйне беркайчан да күргәне булмады.

Әмма бу җәйнең әле озак газаплы елларга сузыласын Фәргать белми иде...

Һәм үзенең башка беркайчан да Гөлҗиһанның нурлы йөзен күрмәячәген ул белми иде...

Караболак, Иртәш тирәләрендә берничә ел рәттән көчле корылык булды, елга-күлләр тәмам саекты, кипте. «Маяк»-ның атом калдыклары ташлый торган Карачай күле дә күз алдында кырый-кырыйларыннан кибеп бетте, төбендә агулы ләм утырып калды. Ул кибеп, тирә-якка радиация нурлары таратып ята башлады. Бары тик күлнең уртасында гына агулы су тибрәлә иде. Тирә-яктагы татар авылларына, бигрәк тә Иртәштә яшәүчеләргә чираттагы атом афәте нәкъ менә Карачай күленнән килер дип беркем дә уйламагандыр, мөгаен. Ә бәла, өермә-давыл булып, эссе җәй уртасында көтмәгәндә башлана...

Башта ап-аяз көндә Уралтау өстендә яшен камчылары ялтырап китә һәм көчле күк күкрәү ишетелә. Әмма бу күк күкрәү үтеп китми, ул тоташ гүләүгә әйләнә һәм Иртәш өстенә килә башлый. Кешеләр, котлары чыгып, бу шомлы гүләүнең кайдан килүен белергә теләгәндәй, бер — күккә, бер аяк астына карыйлар. Ул арада күк йөзе кинәт кенә караңгыланып китә һәм өермә башлана. Бу якларда аны «пәри туе» диләр. «Пәри туе» нечкә генә тузан баганасыннан башлана да, көчәйгәннән-көчәя барып, юлындагы карагай-наратларны сындырып, елга-күлләрнең суын үзенә суырып алып, үкереп торган өермәгә әйләнә. Урал аръягында, Иртәш — Караболак буйларында мондый өермәләр еш була һәм күп вакытта ул бәла-казалар белән бетә.

Бу юлы да нәкъ шулай булды.

Җәй уртасында күктән тавык йомыркасы зурлыгында боз ява башлады. Давыл көченнән өй түбәләре шатырдап җимерелде, тукталышлардагы такта алачыклар чәлпәрәмә килде, тәрәзә пыялалары коелып төште. Әмма иң куркынычы бу түгел, иң коточкыч хәлләр Карачай күле буенда бара иде. Өермә Карачай күле өстенә төшеп, аның кипкән агулы ләмен, суы-ние белән бергә кубарып алып, шәһәр һәм авыллар өстенә алып китә. Ул көнне Иртәш өстенә, тирә-яктагы авыллар һәм урман-кырлар өстенә чын мәгънәсендә радиоактив яңгыр ява. Күктән, кисәтү булып, өермә төшкән һәм ул дөньяга бер миллион кюри атом калдыклары таратып ташлаган иде. Һәм бу тирәдә яшәүче тагы илле мең кеше нурланыш авыруы алганнар иде.

Фәргатьләрне, бөтен полклары белән, Карачай күлен күмәргә ыргыттылар. Кырык биш гектарга сузылган үле күлнең яртысыннан артыгын бетон блоклар һәм кыя ташлары белән бастырып, күмеп куялар, сулы өлеше исә шул хәлдә кала. Күлне күмүдә эшләгән солдатларга һәр көн яңа өс-баш, резин итекләр бирәләр, файдаланганын шунда ук җиргә күмәләр. Әмма шулхәтле кешенең эшен кем карап өлгерсен дә, бернәрсә белмәгәч, кем тәртип сакласын? Солдатларның бер киемнән берничә көн эшләгән вакытлары да була, кайберәүләр, файдаланган яхшы өс-башны ташларга кызганып, посылка итеп туган якларына җибәреп яталар. Чөнки кешеләр моның ни дәрәҗәдә куркыныч икәнлеген белмиләр. Әлбәттә, бу посылкаларны алучылар да берничә елда кибеп-корып, саргаеп үлеп китәләр, моның сәбәбен һичкем аңлата алмый.

Радиацияле Карачай күлен күмгән солдатлар көнаралаш ял итәргә һәм махсус тукланырга тиеш булсалар да, моның белән беркем хисаплашып тормый, аларны һәр көн иртәдән кичкә кадәр атом зонасында тоталар. Һәм һәр көн мәҗбүри аракы эчерәләр, имеш, аракы радиацияне бетерә. Бу — атомчыларның чираттагы ялганы була, алар кешеләрне шулай исертеп радиация арасында эшләргә мәҗбүр итәләр. Соңыннан галимнәрнең әйтүе буенча, алкоголь радионуклидларның канга таралуын тизләткән генә була. Һәм аракы эчүчеләр арасында нурланыштан үлүчеләр өч тапкыр күбрәк булганлыгы билгеле була.

Фәргать кебек таза, нык егетләрне эшнең иң авыр һәм иң куркыныч урыннарына, атом тузаны ургылып торган җирләргә билгелиләр. Биредә нигәдер күпчелек татарлар һәм казах-кыргызлар эшли. Әмма аларны куркыныч турында кисәтмиләр. Иртәштә инде өч елга якын хезмәт иткән Фәргать биредә нәрсә ясаганнарын яхшы белә. Әмма ул да атом радиациясенең кеше өчен ни дәрәҗәдә куркыныч булуын аңлап бетерми, кая куйсалар, шунда бара. Хәер, солдатның башкача эшләргә нинди хокукы бар соң, бу илдә приказны тыңламаган өчен аны трибунал, төрмә көтә бит.

Шулай да Фәргать үзе белгән саклык чараларын үтәргә тырышты — һәр көн өс-башын алыштырды, һәр кичне яхшылап юынды, ә менә бирелгән аракыны эчмәде, якын да китермәде. Татар баласы бу агуның үзеннән курка иде әле. Атна-ун көн эссе тузан арасында эшләгәч, егетләрнең кайберләре күзгә күренеп хәлсезләнә башлады, каты авырып китеп, эшкә чыга алмаучылар да бар иде. Кемнеңдер күз алдында авыз-борыныннан шаулап кан китә, кемнеңдер эче тотмый, күл буенда укшып, косып ятучылар да күренә баш-

лады. Аларны җыеп алалар да тиз генә Сөнкүл буендагы ярымутрауга күчерәләр.

«Мендаркин мыс» дип аталган бу урында шундый авыруларны тоталар икән. Заманында бирелә Златоуст купецының бай сарайлары булган, диләр, революциядән соң ул йортларны туристик база итеп файдаланганнар, ә сугыш вакытында анда хәрби госпиталь булган. 1946 елда Иртәштә атом комбинаты төзи башлагач, Берия солдатлары бирегә килеп, ярымутрауны чәнечкеле тимерчыбыклар белән уратып алалар. Бирегә әсирләрне куып китерәләр һәм алар өстендә радиация тәэсире буенча тәҗрибәләр уздыра башлыйлар. Әсирләр арасында немецлар да, яһүдиләр дә, татарлар да була. Бу яшерен объект НКВДның тугызынчы идарәсенең «Б» лабораториясе дип атала һәм бирелә тере кешеләр өстендә атом тәҗрибәсе уздырыла. Иртәштә көчле нурланыш алган өметсез авыруларны да бирегә китерәләр һәм алар моннан инде беркайчан да исән-сау чыга алмыйлар. Карачай күлендә эшләгән күп солдатларны, шул исәптән татар баласы Фәргатьне дә шул язмыш көтә иде.

Берничә көн радиоактив тузаннар очып торган күл төбендә алмашсыз эшләгәч, әзмәвердәй Фәргатькә дә әллә нәрсә булды. Ул кинәт кенә үзендә көчле хәлсезлек сизде, күңеле болгана башлады, эче кисеп-кисеп авыртырга тотынды. Ул башта моңа игътибар итмәскә тырышты, узар әле дип уйлады һәм шул хәлендә икенче көнне дә эшкә чыкты. Чөнки яңгырлар, җил-давыл башланганчы, күл төбен күмеп бетерергә кирәк иде, аларга шундый әмер бирелгән. Ә эшләрдәй солдатлар саны көннән-көн кими бара. Ул көнне Фәргать берничә егет өчен берүзе эшләде, зур-зур блокларны, ташларны тузан тузгып торган күл төбенә ялгызы урнаштырды, баш күтәрми, көне буе шунда кайнашты.

Кинәт кенә Казахстан чүлләреннән исә башлаган кайнар җил егетне бетон блокларга китереп сылады, ул, башы әйләнеп, җиргә ава язды. Ул арада күмелмәгән күл төбендә тагы «пәри туе» башланды, авыр ташлардан изелеп тузанга әйләнгән ләм, бөтерелеп, баш очында тузгырга тотынды. Бу кызуда битлектән дә сулап булмый, битлексез дә ярамый. Фәргать тыны бетә баруын, буылуын сизде, башы белән очлы ташларга аумас өчен, күлнең капланмаган ләмле өлешенә таба атлады һәм, аңын җуеп, кап-кара упкынга очты.

Аның янына кызыл погонлы НКВД сакчылары йөгерешеп килеп җиттеләр. Берсе тиз генә Фәргатьнең битлеген салдырып карады — солдатның йөзе мәеттәй саргайган һәм күзләреннән... күзләреннән канлы яшь ага иде...

— Беткән бу. Списать итәргә.

Шул сүз белән сакчылар Фәргатьне күл читенә чыгарып

аттылар. Ул кичкә кадәр кызу кояш астында, атом тузаны эчендә аңсыз ятты. Кичкә таба бөркәүле санитар машинасы килеп, аны һәм тагы аңсыз яткан берничә солдатны Сөнкүл буендагы махсус лабораториягә алып киттеләр. Бу солдатларның үле икәнлеген дә, тере икәнен дә белүче юк, әмма нинди хәлдә дә аларның һәр әгъзасы фән өчен кирәк иде. Чөнки бу кешеләр атом казанында булып, һәр күзәнәкләре радиация белән агуланган, шул сәбәпле фәнгә яңа ачышлар ясарга ярдәм итәрлек мәхлуклар иде.

Берничә айдан солдат хезмәтен тутырып Караболакка кайтырга, Гөлҗиһанга өйләнергә җыенган Фәргать өчен, инде үлеп яткан татар егете өчен, билгесез тормыш башланды. Бу — аждаһа авызындагы тормыш иде, атом өстәленә тәҗрибә өчен бәйләп салган хайван тормышы иде. Әмма бу хакта Фәргать үзе белми иде әле.

Фәргать берничә көн яшәү белән үлем чигендә булды.

Чиксез каты авыртудан, бөтен эчке әгъзаларының ут булып януыннан, һәм шуларны тоя алуыннан ул үзенең әлегә исән икәнлеген белде. Әмма үзе белән нәрсә булганлыгын аңламады. Ул әле үлмәгән, тере икән, нигә аның белән берәр нәрсә эшләмиләр, хәлен җиңеләйтмиләр, бу газаплардан коткармыйлар соң? Инде үлеп бара икән, нигә тизрәк үлми, нигә адәм түзә алмаслык авыртулардан газаплана? Нигә аның бөтен бите бинт белән чорналган, нигә күзләрен каплаганнар, нигә ул телен тибрәтеп сүз әйтә алмый? Пәһлевандай егет, ыңгырашып, ярдәмгә чакыра, әмма аны ишетмиләр. Ә ул аларның сөйләшкәннәрен ишеткән кебек була, әмма берни дә аңлый алмый. Нәрсә булган соң аңа, нигә һаман аның хәле җиңеләйми, нигә һаман бөтен тәнендә, эчендә үткен пычак белән айкаган кебек көчле авырту?

Авыруы бераз җибәргән кебек тоелгач, аның битендәге бинтларны сүтеп алганнарын хәтерли. Менә сүтеп тә бетерделәр, менә ул күзләрен ачты, әмма... Әмма ул берни дә күрми иде!!! Тирә-якта тавышлар ишетелә, янында кешеләр басып торганлыгы сизелә, әмма ул аларны күрми иде! Ул күрми, сукырайган, сукыр калган иде!!!

Шушы фаҗигане аңлагач, егет яткан урыныннан сикереп торырга итте, әмма көчле авыртуга түзә алмыйча, чалгы белән чапкандай, кире ауды. Ул бер мизгел аңын җуеп, тын ала алмыйча ятты, эчендәге көчле авырту бер мәлгә күзләре хакында да оныттырган кебек булды. Аңа тизрәк нидидер уколлар ясадылар, көчләп дару эчерделәр, тизрәк тынычландырырга ашыктылар. Чалып ташланган мал кебек, берара ул шулай урынында тынып, таралып ятты... Аннан, күз алдындагы кара бушлыкка карап, сорап куйды:

— Мин күрмим, нәрсәдән бу?

Аңа җавап бирергә ашыкмадылар. Бу сорау җавап бирерлек түгел иде.

Егет башка төрле сорау биреп карады:

— Мин шулай сукыр калачакмынмы?

Янындагы хатын-кыз урыс телендә аны юатырга тырышты:

— Син яшь әле, борчылма, — диде ул, йомшак тавыш белән. — Күрмәвең вакытлы гына булырга да мөмкин, андый хәлләр була. Иң мөһиме — син исән бит, дүрт саның исән...

— Алайса, нәрсә шулхәтле яндыра соң минем эчемне? — дип сорады Фәргать, кара бушлыкка карап. — Утлы пычак белән айкаган кебек.

Бушлыктан килгән тавыш аны һаман юатырга, тынычландырырга тырыша...

— Анысы да үтәр. Туйга хәтле төзәлер, менә күрерсең.

Туй диюгә, Фәргатьнең йөрәге тибүдән туктагандай булды.

Туй?! Туй... Күрше кызы Гөлҗиһан белән никах туе. Тукта, хәзер нинди көн соң, кайсы ай? Ул бу хәлендә озак ятамы? Гомумән, кайда ята соң ул — Иртәштәме, әллә башка җирдәме?

— Син хәрби частьның больницасында ятасың, — дип җавап бирделәр аңа, урынны ачыкламыйча гына. — Инде сентябрь керде, көз җитә.

Көз...

Фәргать, үзе дә сизмәстән, ыңгырашып куйды. Юк, тән авыртканнан гына түгел, җан сызлавына түзә алмыйча бәреп чыкты аннан бу аваз. Бу көздә Фәргать, армия хезмәтен тәмамлап, Караболакка кайтырга тиеш иде бит. Аларның Гөлҗиһан белән туйлары булырга тиеш иде. Бүгенге көндә ул — дөм сукыр инвалид, кирәк булырмы ул Гөлҗиһанга? Ә бәлки әле яңадан күрә башлар, аякка басар, бәлки, шуңа кадәр бу хакта беркемгә дә хәбәр бирмичә торырга кирәктер? Фәргать өчен иң авыр хәл — кеше кулына калу, кеше кулына карап яту иде. Аның өчен иң түбән хәл — сөйгәне алдында мескен, беткән кеше булып күренү. Һәм ул бу хакта берәүгә дә бер хәбәр бирмәскә, бу хәлләрнең азагын көтәргә булды.

Больницада шактый яткач, янәшәсендәгеләр белән аралаша торгач, Фәргать үзе өчен тагы куркыныч яңалыклар белде. Ул Карачай күлен күмгәндә бик көчле радиация алган һәм чак кына үлемнән калган икән. Сукыраюы да шуннан икән. Аның тәне генә түгел, эчке органнары да көчле нурланыш алган, атом утында янган булып чыкты. Ул яшәү белән үлем арасында бәргәләнеп ятканда, аңа берничә операция дә ясаганнар, бу көчле авыртулар шуннан икән. Аның белән нәрсә эшләгәннәр, кайсы җирләренә пычак тидергән-

нәр — Фәргать бернәрсә дә белми. Әмма аның өчен үлем карары булып яңгыраган хәбәр — Фәргатьнең балалары булмаячак икән. Һәрхәлдә, бу чорда. Алга таба нәрсә булыр — беркем дә бернәрсә әйтә алмый. Ягъни ул егерме бер яшендә дөм сукыр булып, эче-башы туракланган хәлдә, бала булдырырга сәләтсез бер гарип булып калган. Һәм биредә күбесе аның кебек ярым үлекләр ята иде.

Фәргать хәзер генә үзенең хәлен аңлады.

Әйе, ул — исән, әмма мондый исәнлектән нинди мәгънә, тере мәет булгач?! Караболакка кайту, Гөлҗиһанга өйләнү турында инде сүз дә була алмый. Уналты яшьлек кыз балага нигә мондый гарип ир? Кызганып, бәлки, ул ризалашыр да, чөнки Гөлҗиһан бик кешелекле кыз, әмма Фәргать, үзен кызгандырып, кешегә йөк була алмый. Ул бу хәлендә беркемгә дә күренергә теләми, хәтта сөйгәненә дә. Ә алга таба нишләргә кирәген ул үзе дә белми. Әниләренә Миасска ул үзенең исәнлеген хәбәр итәр, ә кайтуын — анда да кайтмас, аларга да йөк булмас. Бераз аякка басканчы, бер-бер төпле фикергә килгәнче, ул шушында калырга булды. Күңелендә, бәлки әле күзе ачылыр, бәлки, табиблар нидер эшли алыр дигән яшерен өмете дә бар иде. Ул Сөнкүлдәге бу больницаның радиация алган кешеләр өстендә сынау үткәрүче лаборатория икәнлеген белми иде әле. Белсә дә, аңа барыбер иде, ул табиблар биргән бөтен даруларны эчеп карарга, бөтен операцияләргә түзәргә әзер иде. Тизрәк аякка гына бастырсыннар, яңадан кеше итсеннәр.

Фәргать әнисенә биредә өстәмә хәрби хезмәткә каласын хәбәр иттерде, Гөлҗиһанга бер хәбәр дә бирмәде. Авыр булса да, ул хәзергә күңеленнән Гөлҗиһан белән араны өзде. Аңа хәзер шушы хәлендә — дөм сукыр һәм ялгыз килеш яшәргә өйрәнергә, тормышка җайлаша башларга кирәк иде. Ул әле бу авыру белән, ачы язмышы белән көрәшеп караячак, Гөлҗиһанны кара кайгылы тормышына өстерәп кертмәячәк. Язмышын җиңә ала икән — ул Гөлҗиһанны үзе эзләп табар, юк икән — мәңгегә онытыр, мәңгегә шушы шәһәрдә, шушы хәлендә калыр. Калган гомере, кабере дә шушында булыр.

Шулай итеп, Фәргать Гөлҗиһан өчен кинәт кенә юкка чыга.

Билгеләнгән вакытта армиядән кайтмый.

Билгеләгән вакытта туй булмый кала.

Ата нигезендә яңа гаилә корылмый.

Күрше егете Фәргать, суга төшкәндәй, юк була, эссез югала...

Ә Фәргать Сөнкүлнең лаборатория-больницасында ятып кала. НКВД карамагында булган бу учреждение үзенең ае-

руча яшеренлеге һәм катылыгы белән аерылып тора. Иртәштә һәм тирә-як авылларда нурланыш, рак белән авыручылар шулхәтле күбәеп китә, аларны дөньядан яшереп дәвалау өчен махсус хастаханәләр кирәк була башлый. Чөнки моңа кадәр күренмәгән мондый авыруларны башкалар янына салырга, кеше күзенә күрсәтерә ярамый иде. Бигрәк тә бу авыруларның гарип-гораба балалары туа башлагач, галимнәр эшнең ни дәрәҗәдә куркыныч булуын аңлап алалар. Радиациядән алган нурланыш авыруы кырык буынга җитеп, нәселне җимерә, кешеләрне гарип итә, дөньяга мутантлар туута сәбәп булуы ачыклана башлады. Бу тирәләрдә ике башлы, балык койрыклы балалар туа башлый, буш баш миле, сыңар бөерле, авыш йөрәкле, сукыр, чукрак, телсез балалар туу очраклары да күбәя. Боларның барысын да дөнья күзеннән яшерергә, аерым хастаханәләргә урнаштырырга кирәк була.

Иң башта андый больницаны Иртәшнең үзендә, Сөнкүл буенда ачалар. Биредә радиациядән чирләүчеләр өстендә өряңа дарулар сынап карыйлар. Аннан ФИБ, ягъни физика-биология институты дип аталган мондый лаборатория-больница Чиләбедә дә ачыла, аларның үзәге исә Мәскәүдә иде. Әмма Сөнкүлдәге «Б» лабораториясе үзенең тере кешеләр өстендә уздырган тәҗрибә-сынаулары, рәхимсезлеге белән аерата аерылып тора. Әллә инде анда дөньякүләм танылган әсир немец галимнәре эшләгәнгә, бу урынны халык телендә «концлагерь» дип атап йөртәләр иде.

Атом бомбасы ясау сере нигездә немецлардан урланган булганлыктан, радиация нәтиҗәләрен өйрәнү тәҗрибәсе дә аларда бар иде. Радиобиология фәне, тере организм өстендә радиация тәэсирен өйрәнү немецларда сугышка кадәр үк шактый югары дәрәҗәгә куелган иде. Шуңа күрә сугыштан соң, атом өлкәсендә эшләгән бөтен немец галимнәрен, кайсын әсир итеп, кайсын килешү буенча, Иртәш буйларына куып китерделәр һәм Сөнкүл лабораториясенә яптылар. Шулай итеп, атом буенча бөтен дөньяга даннары таралган Штульдреер, Борн, Кач, Риль кебек атаклы немец галимнәре советлар өчен эшли башладылар. Берәүләр Курчатовка ураннан плутоний аерып алу серен өйрәтсәләр, икенчеләр радиобиология өлкәсендә үзләренең Берлин тәҗрибәләрен биредәге авырулар һәм әсирләр өстендә уздыра башладылар. Гитлер башлаган бу мәкерле эшне Сталин һәм Берия дәвам итте, кешеләр өстендә Германия концлагерьларында башланган атом тәҗрибәсе Иртәш буйларындагы Сөнкүл лабораториясенә күчте.

Татар егете Фәргать шушы ак халатлы палачларның тәҗрибә өстәленә салынган чираттагы корбаны иде.

## Унбишенче бүлек

Инде билгеләнгән туй вакытлары үтеп китеп, кара күзләргә кергәч, Нәбиулла, кызына сиздерми генә, Миасска, Фәргатьнең әнисе янына барып кайтырга булды. «Солдат хезмәте бит, ни булмас, — дип уйлады үзе дә сигез еллап армиядә йөреп кайткан ата кеше. — Кыз да кызганыч, авыл халкыннан да яхшы түгел, чөнки туй турында хәбәр инде күптән таралды. Туй дип Гөлҗиһан җәен укырга керергә дә бармады, эшкә дә урнашмаган, хәзер инде ни дә булса хәл итәргә кирәк...» Хәзер инде барысы да Нәбиулланың Миасстан нинди хәбәр белән кайтуыннан тора. Исәнме Фәргать, юкмы, исән икән, ник бер хәбәр бирми, нигә кыз баланы ил алдында мондый хәлгә калдырды? Гөлҗиһан күзгә карап сула бит, эчтән өзгәләнә, кешегә сиздерәсе килми баланың, эчтән яна. Ул тәмам олыгайды, җитдиләнде, сөйләшмәс, көлмәс булды. Әйтерсең Караболак күгендә якты бер йолдыз сүнде. Һәм Нәбиулла, бу билгесезлеккә чик кую өчен, үзе җыенып юлга чыгып китте. Хәзер инде барысы да аның нәрсә дип кайтып әйтүеннән тора иде.

Әмма ул Миасста Фәргать турында артыгын белә алмады. Дөрес, аның исән-сау икәнлеген белде ул, анысы да бүгенге көн өчен зур нәрсә иде. Фәргать Иртәштә өстәмә хәрби хезмәткә калган булып чыкты, әнисенә ул бу хакта үзе хәбәр иткән. Анысы да була торган хәл, тик нигә бу хакта Караболакка, Гөлҗиһанга да хәбәр бирмәгән ул? Туй булырга торганда, араны нигә кинәт кенә шулай өзгән? Әллә араларында берәр аңлашылмаучылык килеп чыкканмы? Яшьләр бит, икесе дә кайнар, икесе дә горур. Ата кеше кызы өчен шулай Уралларга килеп, төпченеп йөрүенә уңайсызланып та куйды. «Ярый, исән икән исән, насыйп булса, бер күрешерләр, язган булса, өйләнешерләр, — дип уйлады ул. — Кыз әле бик яшь, укырга керер, һөнәр алыр. Тормыш корырга өлгерер әле...»

Нәбиулла Миасста артыгын төпченеп тормады. Төпченгән булса, ул Фәргатьнең бирегә дә бер хат язмавын, Иртәштә калуы турында телеграмма белән генә хәбәр итүен белер иде. Төпченгән булса, монда нидер булуын сизенер иде. Әмма Фәргатьнең әнисе дә, Гөлҗиһанның әтисе дә телеграммага ышандылар һәм аны эзләтеп тормадылар. Хәер, ябык атом шәһәреннән ничек эзләтергә мөмкин булыр иде аны? Һәм алар барысы да Фәргатьнең хәбәр бирүен көтеп яши башладылар.

Ә бу вакытта дөм сукыр Фәргать Сөнкүлдәге Берия лабораториясендә яшәү белән үлем арасында бәргәләнә иде...

Ата кеше Караболакка кайтып кергәч тә, бу хакта кызына озак кына әйтә алмый йөрде. Әйтмәс тә иде, Гөлҗиһанның ничек эчтән януын, билгесезлектән өзгәләнүен күрде.

— Фәргать Иртәштә хәрби хезмәттә калган, кызым, — диде ул, Гөлҗиһанның ялгыз калган чагын туры китереп.

Гөлҗиһанны ток суккандай булды. Аның битләре баштa кып-кызыл булып чыкты, аннан кар кебек агарды. Алай да кыз үзен кулга алып өлгерде, газаплануын беркемгә дә, хәтта әтисенә дә күрсәтәсе килмәде.

— Ә син кайдан белдең, әти? — диде ул, мөмкин кадәр тыныч тавыш белән.

— Миасска барып кайттым мин, кызым, — дип, дөресен әйтергә булды Нәбиулла. — Әнисенә телеграмма белән хәбәр биргән ул, Иртәштә өстәмә хәрби хезмәткә калган.

Гөлҗиһан җавап итеп бер сүз дә әйтмәде. Иелә барган башын югары күтәрде, бугазына килеп төелгән әрнүен эчкә йотты, сер бирмәде. Атылып чыгарга торган хыянәтче күз яшьләрен әтисенә күрсәтмәс өчен, ялт итеп тәрәзәгә борылды, ясалма шаян тавыш белән:

— Калган икән калган инде, — дип әйтеп куйды. — Һәркемнең үз эше, әти.

— Әйе, кызым, һәркем үзе хәл итә, — дип җөпләде аны ата кеше. — Быел укырга керергә соңга калдың инде, киләсе ел өчен әзерләнә башларсың. Кышын эшләп алсаң да була, ничә тапкыр мәктәпкә чакыра килделәр бит.

Аның кызын Фәргать турында уйлавыннан читкә алып китәсе килде, Гөлҗиһанга тизрәк нинди дә булса шөгыль табарга ашыкты. Гөлҗиһан да әтисенең бу сүзенә чат ябышты, аңа барып чыкмаган туй хурлыгын тизрәк онытырга кирәк иде. Ә моны бары тик эш белән генә бастырырга була, авыз салындырып елап утырмас бит инде Гөлҗиһан башы белән.

— Әйе шул, әти! — диде ул, башын горур тотып. — Иртәгә үк эшкә мәктәпкә барам! Ничә тапкыр чакыра килделәр бит инде.

Гөлҗиһан шулай диде дә, ниндидер эш тапкан булып, ишегалдына чыгып йөгерде. Керфек очларына менеп кунаклаган күз яшьләрен әтисенә күрсәтәсе килмәде аның. Аның хәзер бөтен кешедән дә качасы, дөньядан качасы килә, ул башында ут булып кайнаган бер генә соравына да җавап таба алмый. Ә анда — Фәргать, Фәргать, Фәргать...

Гөлҗиһан атылып урамга чыкты...

Ә анда, бөтен дөньяны энҗе нурларга күмеп, беренче кар ява иде! Менә ак кар бөртекләре Гөлҗиһанның озын керфекләренә куналар, кызыл иреннәренә төшеп эриләр, кызның күз яшьләренә кушылып, ут булып янган битләре буй-

лап агалар. Быел Караболакта беренче кар шулай елый-елый ява, елый-елый ага. Узган ел, Фәргать ялга кайткач, алар ак кар яуган Караболак урамнары буйлап кич буе җитәкләшеп йөргәннәр иде. Ярәшелгән парлар булгач, аларны авылда беркем дә гаеп итмәде, барысы да, алар өчен сөенеп, туй көнен көттеләр. Чөнки гүзәл Гөлҗиһанга тиң булырлык, горур Гөлҗиһанны буйсындырып торырлык башка кеше юк иде Караболакта. Патша кызы кебек үз дәрәҗәсен яхшы белгән Гөлҗиһанны бары тик мәхәббәт кенә буйсындыра ала иде.

— Безнең туебыз кайчан була, Фәргать? — дип сорый иде аннан Гөлҗиһан, шук елмаеп.

— Бу юлы кызыл кар яугач түгел инде, — дип көлә Фәргать тә. — Караболакта беренче кар яуганда булачак безнең туебыз, Гөлҗаным. Нәкъ бер елдан, мин солдаттан кайткач. Көтәрсең бит?!

Гөлҗиһан чытлыкланып көлгән була. Ә эченнән генә ул бу елның һәр көнен, һәр сәгатен саный башлый. Көтмиме соң?! Көтмиме?! Ул Фәргатьне янәшәсендә торганда да сагына, киткәч, һәр көн аңардан хат көтә, бары тик шуның белән яши. Ул аннан ояла да, аңа гел тартыла да, сагына да, дөньяда ул булганга сөенә дә. Фәргатькә гашыйк булганнан бирле, Гөлҗиһан авыруның да нәрсә икәнлеген онытты, ул бары тик киләчәккә хыял-өметләр белән генә яши. Аларның Караболакта үз өйләре булачак, Фәргать аны күтәртә башлады инде, аның кулыннан бөтен эш килә. Ул өйнең ишегалды тулы аларның балалары булачак. Уллары Фәргать кебек баһадир гәүдәле, көчле һәм батыр, кызлары, Гөлҗиһан кебек, сылу һәм сөйкемле булачак. Гөлҗиһан аларга Караболак тарихын сөйләр, үзләренең Алып Ханнар нәселеннән икәнлекләрен аңлатыр, Биташ күленә алып барыр, урманкырларны, борынгы скиф-һун курганнарын күрсәтер. Ул аларга татар хан бабалары турында Таһирҗан бабай өйрәткән шигырьләрне укыр, татарча җырлар өйрәтер, догалар ятлатыр. Фәргать исә аларга тормыш рәтен өйрәтер, акыл бирер, аларны авырлыклардан саклар. Чөнки шундый көчле, акыллы, рәхимле бит ул Фәргать.

Гөлҗиһан өй артындагы коймага капланды да үксеп елап җибәрде. Юк, юк, ул ышанмый, Фәргать аны болай гына оныта, ташлый алмый, аңа нидер булган, булган! Нигә бер хаты, хәбәре юк аның Гөлҗиһанга? Ул бит андый түгел, һәр көн озын-озын хатлар яза иде, туй көнен сәгатьләп саный иде. Нигә калган ул Иртәштә, нигә бу хакта Гөлҗиһанга хәбәр бирмәгән? Аның соңгы хатлары шактый кырыс һәм коры була башлаган иде бит. Әллә соң Иртәштә башка хатынкызны очраттымы икән ул?

Көтелмәгән бу уеннан Гөлҗиһанны яшен суккандай бул-

ды. Әйе, дөньяда Гөлҗиһаннан башка да хатын-кызлар күп бит, ә Фәргать алар кызыгырлык матур, гәүдәле. Ничек башта ук шул турыда уйламаган соң Гөлҗиһан? Димәк, тормышта болай да була ала? Хыянәт тә була ала. Бәлки, Фәргать Гөлҗиһанны әллә кайчан оныткандыр инде, шәһәрдә башка кызлар тапкандыр...

Бу уеннан Гөлҗиһанның башлары әйләнеп китте, бу юлы инде күзләренә гарьлек яшьләре бәреп чыкты. Ул, ут булып янган иреннәрен канатканчы тешләп, картнәйләренең өенә таба йөгерде. Аның хәзер әтисе янына керәсе килмәде, ул аның күзенә күренергә ояла иде.

Гөлҗиһанның бәхетенә, Таһирҗан бабай да биредә булып чыкты, әйтерсең лә ул аны көтеп кенә торган. Гөлҗиһан да, сыену, ярдәм эзләп, Таһирҗан бабасының күкрәгенә килеп капланды һәм мышкылдап елап җибәрде. Бу мизгелдә аны бары ул гына дөрес сүзләр табып юата алыр кебек иде.

— Ә син борчылма, кызым, барысы да яхшы булыр, иншаллаһ! — диде Таһирҗан бабасы, оныгының уйларын сизгәндәй. — Табышырсыз да кый, кавышырсыз да — язганы булыр, Алла теләсә.

Гөлҗиһан, мөлдерәп, Таһирҗан бабасына күтәрелеп карады. Нинди кавышу турында сөйли ул, кем белән? Каян белгән ул Гөлҗиһанның ни өчен өзгәләнүен?

— Кем белән кавышу турында сөйлисең син, Таһирҗан бабай?

— Кемне уйлыйсың, шуның белән, кызым, — диде бабасы, аның чәчләреннән сыйпап. — Тик сабыр итәргә кирәк, кызым, ашыгып нәтиҗә чыгарма. Дөнья бит бу, анда әллә нәрсәләр булырга мөмкин. Бәлки, аңа синең ярдәм кирәктер.

Бу сүзләрдән Гөлҗиһан сискәнеп китте. Әйе шул, бәлки, Фәргатькә аның ярдәме кирәктер? Гөлҗиһанга аның турында әллә нәрсәләр уйлавы өчен оят булып китте. Каян чыгып аның башка кызлары бар, дип әйтә ала ул? Кеше турында, бигрәк тә яраткан кешең турында, ничек шулай уйларга мөмкин? Бәлки, Фәргать, чыннан да, авыр хәлдәдер, бәлки, аңа, чыннан да, Гөлҗиһанның ярдәме кирәктер?

— Миңа нишләргә соң, бабай? — диде ул, бер карарга килә алмыйча интегеп.

— Сабыр итәргә, кызым, сабыр, — диде бабасы, һаман шул сүзгә басым ясап. — Сабыр төбе — сары алтын. — Аннан бабасы сүзне оста гына башкага борып җибәрде: — Син быел укырга бармадың инде, кызым?

— Шулай килеп чыкты бит инде, — диде Гөлҗиһан, туй сүзен исенә төшерәсе килмичә. — Киләсе елга барырмын, Алла теләсә.

Гөлҗиһанның бу сүзләреннән Таһирҗан бабасы бик канәгать калды:

— Шулай, гел «Алла теләсә» дип әйт, кызым, — диде ул, оныгының аркасыннан кагып. — Кая барырга уйлап торасың инде, кызым?

— Мин Сверлауга юридическийга бармакчы идем, — диде Гөлҗиһан, сүзнең башка якка кереп китүенә куанып. — Әмма анда кызларны бик алмыйлар икән, армиядән кайткан егетләр күп, ди.

— Кыз бала өчен авыррак хезмәт инде, — диде бабасы, җайлап кына. — Кыз бала өчен укытучы, табиб эше яхшы инде ул, кызым. Өйдә дә, эштә дә ярый торган хезмәт.

Ул арада сүзгә Нурҗамал әбисе дә килеп кушылды:

— Гомерем буе нәселебездә бер укыган табиб булсын иде дип кызыктым, — диде ул, үз фикерен әйтеп калырга ашыккандай. — Гөлҗиһан кызым яхшы укыганга бик сөенгән идем, табиблыкка китәр дип. Әллә нәрсә килеп чыкты бит менә. Хәерлесе булсын инде.

Ә Гөлҗиһанның бу турыда уйлаганы да юк иде! Әйе, ул бик яхшы укыды, мәктәпне бишкә генә тәмамлады. Аңа уку да, эш тә, кешеләр белән аралашу да бик җиңелдән бирелә иде, ул бер җирдә дә интекмәде, көчәнмәде. Мәктәптә бөтен яктан аңа тиңнәр булмады, укуда да, матурлыкта да, батырлыкта да аны беркем җиңә алмады. Барысы да башта Гөлҗиһан әллә кайларга барыр, әллә кемнәр булыр дип көттеләр. Чөнки ул кайда барса да укырга керә ала иде. Аннан Фәргать килеп чыкты. Гөлҗиһан аннан башка тормышын күз алдына да китерә алмады, кая анда укырга китү, кемдер булу. Ул кияүгә чыгарга сандык малы әзерли башлады, өй, гаилә, итәк тулы балалар турында хыялланды. Әнә Нурҗамал әбисенә хәтле, аның укып, нәселдә зур кеше булуын көткәннәр икән. Табиб булыр дип хыялланганнар. Көтелгән туй булмагач, барысының да беренче сүзләре уку турында булды. Бәлки, бу Гөлҗиһанның уй-гамәлләрен башка юнәлешкә алып кереп китү өчен махсус эшләнгәндер, бәлки, олылар чыннан да, Гөлҗиһанның нәселдә бер зур кеше булуын өмет иткәннәрдер.

Ни булса да, бу сөйләшүләрдән соң Гөлҗиһан өйләренә шактый тынычланып, җитдиләнеп кайтып керде. Әтисе белән Фәргать турында сөйләшүләр дә каядыр еракта, пәрдә артында калган кебек тоелды аңа. Әйе, Таһирҗан бабасы дөрес әйтә — аңа бу мәсьәләдә сабыр булырга кирәк. Ашыгып нәтиҗә чыгарырга ярамый, насыйп булса, бар да ачыкланыр, беленер. Иртәш дөнья читендә түгел, Караболактан да анда күп кеше эшли, Фәргать анда булса, берсе ишетмәсә, берсе ишетер, берсе күрмәсә, берсе күрер. Аның турында дө-

рес хәбәр авылга барыбер кайтып җитәр, Алла теләсә. Бәлки әле, үзе дә хәбәр бирер. Ә хәзергә Гөлҗиһанга үзенең киләчәге турында уйларга кирәк. Аның классташлары күбесе кайсы укырга, кайсы эшкә урнашып бетте инде, авылда Рәшидә кебек авырулар гына калды. Авылда авырулар һаман бик күп, әмма халык бу хәленә ияләнеп бара инде. Караболак халкы, гомумән, зарланырга, чирен кешегә күрсәтергә яратмый. Югыйсә һәр йортта диярлек ятып чирләүче бар бит инде.

Боларны искә төшергәч, Гөлҗиһан табиб булу турында җитдирәк уйлый башлады. Әбисе дә әнә, табиб бул, ди. Теге вакытта, кан косып, үлемнең күзенә карап ятканда, Гөлҗиһанның үзенең дә табиб буласы килгән иде. Ул шулхәтле каты сызланды, авырды, ә шул чакта янында хәлен җиңеләйтерлек бер табиб булмады. Авызына бер дару каптыручы да булмады, әле ярый әби-бабасының үләннәре, сулары булды. Ул вакытта авылда Гөлҗиһаннар классыннан гына да җиде бала үлде, яннарында ярдәм итәргә табиб булса, бәлки, алар исән калырлар иде. Медицина көчле булса, бәлки, Хәбибулла абыйсы да исән калыр иде, утыз яшендә үпкәләре череп үлмәс иде. Аннан соң да аларның Сәкәлин урамында гына да иллеләп кеше үлде инде, барысы да яшьләр һәм балалар. Чыннан да, нидән үлә икән алар? Нигә моны беркем дә тикшерми икән? Нигә алар авылында табиб юк икән? Медпункт урыс авылы Кояшта, больница алтмыш-җитмеш чакрымдагы район үзәгендә. Дөрес, һәр елны мәктәпкә килеп, балаларның беләкләреннән кычкыртып каннарын алып тикшереп йөргәннәр иде урыс табиблары. Әллә Мәскәүдән, әллә Чиләбедән, диделәр аларны. Әмма аларның ул тикшерүләреннән авыл халкына ни мәгънә соң, авыруларыннан дәваламагач?

Ә ярты мәктәп чирле бит алар авылында, әле бөтенесе дә булмаса. Кемнең чәче коелган, гел пеләш калган, кем начар күрә, ә авылда күзлек юк. Кайбер балалар кинәт кенә артык симереп киттеләр, аякларын чак өстерәп йөри башладылар, ә кайберәүләр артык ябык, карарга куркыныч. Балалар шундый була димени? Аларның Гөлҗиһаннан соң туган энеләре дә гел чирли, әти-әнисе нишләргә дә белмиләр. Бәлки, бу хәл тимерчыбык белән әйләндереп алган Караболак суын эчкәнгәдер? Бәлки, Караболакның туфрагы агулыдыр? Алай дисәң, халык гомер буе шушында яшәгән бит инде, туксанга, йөзгә җиткәннәр. Ә хәзер Караболакта кеше тууга чирли башлый яки туганда ук чирле туа. Димәк, кияүгә чыкса, Гөлҗиһанның балаларын да шул хәл көтәргә мөмкин?

Гөлҗиһанның башына башка уйлар керде.

Ул дөньяга башка күзлектән карап, башкача күзәтә башлады.

Кышын ул укытырга Караболак мәктәбенә барды, аңа башлангыч классларны бирделәр. Гөлҗиһан балаларның бик тиз аруларына, хәлләре бетүенә игътибар итте, хәтта аң җуеп егылу очраклары да бар иде. Авыл баласы, гадәттә, нык, таза була, юк-барга гына селкенми дә. Ә монда балалар аңсызланып егылалар, гел баш авыртудан, эч авыртудан зарланалар, начар ишетәләр, начар күрәләр. Гөлҗиһан үзе укыганда да балалар арасында авырулар бар иде, әмма бу дәрәҗәдә түгел иде. Нинди хәл булыр икән соң бу? Нигә болар белән беркем дә кызыксынмый, хисабын алмый? Шушы сораулар алдында Гөлҗиһанның үз хәсрәте, Фәргать кайгысы да онытылыбрак торган кебек булды.

Чиләбе табиблары Караболакка чираттагы тикшерүгә, кан алырга килгәч, Гөлҗиһан бу сорауны аларга да бирде. Мондый туры сорауны көтмәгән табиблар югалып калдылар, чөнки бу авылда алардан әле берәүнең дә болай терәп сораганы юк иде. Әйе, бу яшь укытучы кызның күзәтүләре дөрес, бу авылда балаларда да, олыларда да бер үк хәл — канның бозылуы, үзгәрүе күренә. Алар барысы да дип әйтерлек каннарында атом тамгасы йөртәләр, бу исә төрле авыруларга, хәтта гариплеккә, баласызлыкка, үлемгә дә китерергә мөмкин. Әмма моны аларның үзләренә ничек әйтәсең? Сәбәбен сорый башласалар, ни дип әйтерсең? Моның сәбәбе, әлбәттә, янәшәдәге «Маяк» комбинаты, бу авыллар өстенә туктаусыз таралып торган радиация. Әмма болар барысы да дәүләт сере, бу хакта әйтергә дә, язарга да ярамый. Һәм табибларга да төрлечә алдарга, дөреслекне яшерергә туры килә.

— Татарларда ашау гел бертөрле, яшелчә-җимеш, витаминнар организмга аз керә, шуңа укучыларның хәле юк, — дип җавап бирделәр Чиләбе табиблары, Гөлҗиһанны ышандырырга тырышып.

Ә Гөлҗиһан ышанмады.

Нигә аларда яшелчә-җимеш аз булсын ди? Бөтен бакчалар, урман-кырлар шуның белән тулган бит. Гөлҗиһаннар үзләре генә дә кыярын, помидорын, кишер-кәбестәсен, кабагын, суган-сарымсагын бакча-бакча утырталар, кисмәк-кисмәк тозлыйлар. Ә инде җиләк-җимешне, алманы, карлыган-кураны, чияне җыеп бетерә алмыйлар, алар бакчада да, урманда да, Караболак буенда да чиләк-чиләк җыярлык. Авыл баласы шуларны ашамый диме? Һәркемнең баз тулы вареньесы, умарта-умарта балы, сөте-каймагы — барысы да бар хәзер авылда, беркем ач түгел. Шуңа карамастан барысы да чирле, көн сан кеше үлә, хәтта яшьләр, балалар да.

Гөлҗиһан Чиләбе табибларына менә шуларны аңлатып бирде. Аларның моңа җавабы юк иде.

— Ашауны әйтә алмыйм, — дип каршы төште аңа Мәс-

кәүдән килгән урыс табибы. — Әмма сездә, татарларда, туганнар арасында өйләнешүләр, ягъни кан катнаштыру күп икән... Ә бу, үзегез беләсез, мутациягә, ягъни гариплеккә, нәселнең зәгыйфьләнүенә китерә...

— Юк бездә андый хәл, кем әйтте сезгә моны? — дип чәчрәп каршы төште Гөлҗиһан. — Беркем дә үз туганына өйләнми инде, һәркем үзенең җиде буынын белә. Туганнарга мулла бабай нишләп никах укысын?

Табиблар, аптырашып, бер-берләренә карадылар. Ут кебек кайнар, хан кызыдай горур һәм гүзәл бу татар кызына аларның җаваплары юк иде. Аларга ярдәмгә Коншактан килгән үз «татарыбыз» ашыкты:

— И, сеңелем, кешенең башын юк белән катырма инде, үзең дә белә торып, — диде ул, бөтен сөйләшүгә йомгак ясап. — Халык эчә бит хәзер, шуңа күрә чирлиләр, үләләр. Сездә дә шул хәл, бездә дә.

— Бездә алай түгел! — дип, тагы чәчрәп каршы чыкты Гөлҗиһан. — Бездә алай эчмиләр! Безнең нәселдә беркем эчми, ә энеләрем гел авырый. Теге вакытта мин үзем дә үлә яздым.

— Эчәләр, эчәләр караболаклар! — дип, Коншак хатыны чәт-чәт килде. — Мин әллә сезнекеләрне белмимме? Менә хәзер керсәң, өй саен әче бал. Аракының да кимен куймыйлар. Эчмәгән кеше юк ул хәзер, шуңа күрә чирлиләр дә.

Алар белән бәхәсләшеп торудан мәгънә юк иде, барыбер дөресен әйтмәячәкләр иде. Бәлки әле үзләре дә белмиләрдер. Килгән табиблар Гөлҗиһанны ышандыра алмасалар да, ул уйга калды. Әйе, алар авылында да эчүчеләр күренгәли хәзер, әмма алай ук түгел бит! Ул сабый балаларның, яшь-яшь ирләрнең егылып үлүләрендә эчкечелекнең ни катнашы бар? Хәбибулла абыйсы эчүнең нәрсә икәнлеген дә белми иде, утыз яшендә корып үлде. Ә Фәргатьнең әтисе Якуп абый? Аңа да бит нибары кырык яшь иде, теге вакытта, Иртәштә шартлаган елны, Караболактан кайтуга авырый башлаган һәм ул да кибеп үлде. Ул да гомерендә эчкән кеше түгел бит.

Фәргать исенә төшкәч, Гөлҗиһанның тагы күңеле кузгалды.

«Әллә аңа да берәр нәрсә булдымы икән соң? — дип уйлады ул хәвефләнеп. — Иртәш шартлаган көнне ул да авылда иде бит, аннан соң Караболакта күпме кеше тәгәрәп үлде. Бәлки, авыл егетләрен кырган бу билгесез чир Фәргатькә дә кагылгандыр, бәлки, бу мизгелләрдә ул да үлем көтеп ятадыр?» Бу уеннан Гөлҗиһан чайкалып куйды, тәнендә һәм җанында онытылып торган авырулары кузгалды, башы әйләнеп китте. Аумас өчен, ул тизрәк урынга барып

утырды. Соңгы вакытта Гөлҗиһан үзендә тагы шул авыру билгеләрен — хәлсезлек, баш әйләнү кебек нәрсәләрне сизә башлаган иде. Авыру шундый бит ул — көчсез, бәхетсез чагыңны гына көтеп тора да өстеңә ыргыла. Фәргать турында уйлау, билгесезлек Гөлҗиһанны да тәмам көчсезләндергән, бөгеп салган иде. Ә борчулы уйлары аннан рөхсәт сорап тормыйлар, ургылып, һаман өстенә киләләр, җавап таләп итәләр. Ә җавап юк.

Әйе, Фәргать тә, Хәбибулла абыйсы кебек, Иртәштә яши иде бит. Ә андагы хәлләрне күргән халык бик куркыныч итеп сөйли. Элегрәк анда кертмәгәннәр дә, чыгармаганнар да бит. Хәбибулла абыйсы да шуннан чирләп, корып кайтты. Бәлки, Фәргатькә дә шунда берәр зәхмәт кагылгандыр? Нигә Гөлҗиһан бу турыда элегрәк уйламаган соң? Кем белән сөйләшеп, киңәшеп карарга икән бу хакта? Таһирҗан бабай карт инде, ул Иртәштәге хәлләрне белерлек түгел. Авылда моны теләсә кемгә ачылып булмый, халык үзе дә анда ниләр булганлыгын белми. Бу хакта Гөлҗиһан бары тик әтисе белән генә киңәшә ала. Ул армиядә хезмәт иткән, сугышта булган кеше, дөнья күргән, тормышны белә. Һәм Гөлҗиһанның сорауларына бары тик ул гына җавап бирә алачак. Гөлҗиһан аннан Иртәш турында да, Караболактагы бу хәлләр турында да, Фәргать хакында да ачыграк сорар. Әтисе аны аңлар, әтисе аңа ярдәм итәр.

— Әти, минем синең белән бик җитди нәрсәләр турында сөйләшәсем бар, — диде ул, аның каршына килеп утырып.

Кызының мәктәптәге эше белән мавыгып, үз кайгысын онытып торуына Нәбиулла сөенеп йөри иде. Аның җитди нәрсәләр турында сөйләшергә җыенуын белгәч, бераз аптырап калды. Фәргать турында булса, шуннан артык нәрсә әйтә ала ул аңа? Ул үзе дә Гөлҗиһан белгән хәтле генә белә бит. Ә бәлки, укырга керү турында киңәшәсе килгәндер, көннәр язга авышып бара бит, имтиханнар вакыты да якынлаша...

— Әти, нигә безнең авылда халык шулхәтле күп үлә икән? — дип, турыдан-туры сорап куйды Гөлҗиһан.

Нәбиулла мондый сорауны бөтенләй көтмәгән иде, бераз аптырап, югалып калды, шактый гына дәшми торды.

— Күп үлә шул, кызым, бик күп, — диде ул, башка җавап таба алмагач.

— Ә нигә?

Нәбиулланың моңа төгәл җавабы юк иде. Ул үзе дә хәйран калып йөри — авылда көн саен мәет, көн саен чирле. Гомер булмаган хәл — бөтен тирә-якка данлыклы Караболакта тумыштан тилеләр, әллә нинди гарипләр, телсез-чукрак балалар күренә башлады. Кая анда кешене тикшерергә — үз нәселләрендә әллә нәрсәләр булып ята бит. Туганы Хәби-

булла, япь-яшь килеш, күзгә карап кинәт кенә үлеп китте. Гөлҗиһан үзе чак кына үлемнән калды. Хатыны Хәбирә ике ел рәттән үле бала тапты, Гөлҗиһаннан соң туган малайларда бөтенләй рәт күренми, чирдән башлары чыкмый. Менә күпме вакыт инде Нәбиулланың үзенең дә ниндидер чир-зәхмәт бөтен эчен яндыра, айкый, күкрәген талый, үпкә-бавырын телә. Әмма алар авылында, алар нәселендә чир турында бик сөйләргә яратмыйлар, аны тикшермиләр. Ә Гөлҗиһан әнә күзгә карап җавап көтә.

— Үзем дә аптыраган инде, кызым, — диде Нәбиулла, хак дөресен әйтеп. — Элек безнең авыл халкы бик озын гомерле иде, безнең Алып Ханнар нәселендә хәтта йөз илле яшькә кадәр яшәүчеләр булган, диләр. Күпчелек кеше сиксән-туксанга җитеп, үз үлеме белән картаеп үлгән. Ә хәзер әллә нәрсә китте — яшьләр, балалар үлә бит. Гомер булмаган хәл.

— Ә Таһирҗан бабай нәрсә ди болар хакында?

— Таһирҗан бабаң? Таһирҗан бабаң әйтә ул.

— Нәрсә ди?

Нәбиулла як-ягына карап куйды. Аннан, кызына иелә төшеп, шыпырт кына әйтеп куйды:

— Дөньяны агулыйлар, ди Таһирҗан бабаң. Суда, һавада, туфракта агу бар, ди, шуңа күрә суны Биташтан ташый ул, халыкка да шулай куша, әмма анда чаклы көн дә кем барып йөрсен? Иртәш ягыннан куркыныч килә, ди. Анда ни булганын ул үзе дә белеп бетерми, ул күп нәрсәне сиземләп белә бит, үзең беләсең. Иртәштән сак булыгыз, ди Таһирҗан бабаң…

— Иртәштән сак булырга?!

Гөлҗиһан утырган урыннан сикереп торды. Фәргать тә Иртәштә бит, димәк, ул да шул агу эчендә?!

Әтисе дә урыныннан торып, ишек буйларын әйләнеп килде, тәрәзә пәрдәләрен тартыбрак ябып куйды. Чөнки Караболакта әле озын колак шымчылар да, кирәк урынга җиткереп торучылар да бар иде. Иртәш белән бәйле мәсьәләдә бигрәк тә сак булырга кирәк, анда бөтен нәрсә дәүләт сере бит.

— Теге вакытта Иртәштә нидер булганын күптән сизенә идек инде без, — диде ул, кызы каршына килеп утырып. — Авылдагы бөтен авырулар шул вакыттагы шартлаудан соң башланды бит. Тирә-күрше авылларны юкка гына башка урынга күчермәделәр бит инде. Ниндидер зәхмәт, агулану белән бәйләнгән иде бу хәлләр. Ә без калдык. Хәтереңдә булса, коеларны күмделәр, елгага юлны яптылар, болын-кырларга кертми башладылар. Берничә елдан барысына да яңадан рөхсәт бирделәр тагы.

— Ул вакытта, Иртәштә атом бомбасы шартлаган, дип сөйләделәр бит, әти. Бәлки, шуннандыр халыкның бу авырулары?

Нәбиулла үзе дә белә — авылда бу турыда бераз сөйләшеп алдылар да тындылар. Чөнки авыл халкы өчен атом бомбасы белән гади бомба арасында аерма юк, ул аны белми һәм нинди нәтиҗәләргә китерәсен дә аңламый иде. Хәбибулла да үләр алдыннан «атом, үлем» дип пышылдаган.

— Әгәр ул вакытта Иртәштән ниндидер агу таралган булса, һаман шул суда, туфракта бит инде ул, кызым, — дип дәвам итте Нәбиулла, үзенчә фикерләп. — Әллә, чыннан да, шуннан чирлиме икән соң бу Караболак халкы? Әмма моны ничек ачыклыйсың? Сорасаң да, кем җавап бирер? Иртәштә бөтен нәрсә дәүләт сере бит анда. Анда эшкә кергән авыл егетләреннән кул куйдыралар икән, егерме биш ел дәүләт серен ачмаска дип. Хәбибулла абыең да берни сөйләмәде бит, үлгәндә генә «атом, үлем» дип әйтеп өлгерде. Бәлки, ул безне шулар хакында кисәтергә теләгәндер.

— Эти, әллә Фәргатькә дә берәр нәрсә булдымы икән соң анда? — дип сорады Гөлҗиһан, үз уйларына бирелеп. — Болай кисәк кенә хәбәрсез араны өзәргә тиеш түгел иде бит инде ул, туй була дип торганда.

Ул хакта Нәбиулланың үзенең дә башына килде. Солдат хезмәте бит, ни булмас, бигрәк тә андый хәрби шәһәрдә, атом коралы белән бәйле җирдә. Әмма әниләренә хәбәр биргән бит ул, исәнлеген белдергән.

— Ни булса да, көтеп карыйк әле, кызым, — диде ул, Гөлҗиһанның һаман шул турыда уйлавына борчылып. — Мин дә үз юлларым белән белешермен, бәлки әле сиңа да берәр хәбәр килеп төшәр. Сиңа хәзер укырга барырга әзерләнергә кирәк, кызым, кая барасын хәл иттеңме әле?

— Мин Чиләбегә, медицина училищесына барырга ниятләдем, эти, — диде Гөлҗиһан, уйчан гына. — Нәселгә бер медик кирәк инде. Аннан, насыйп булса, институтына да керермен, хәзергә училищедан башлыйм әле.

Нәбиулла, бу хәбәрне ишетеп, чиксез куанды. Ул Гөлҗиһанга бик зур өметләр баглый иде, чөнки аның акылы, тәвәккәллеге, тырышлыгы ирләргә алыштыргысыз. Үзенең авырый башлаганын сизгәч, Нәбиулла гаиләсе, карт ата-анасы, авыру уллары турында уйлап борчылды, үзе белән бер-бер нәрсә булса, аларны кемгә калдырырмын дип кайгырды. Аның бөтен карап торганы, өмете — кызы Гөлҗиһан иде. Бу бала исән булса, нәсел югалмас, ул берсен дә авыр хәлдә калдырмас, ташламас. Аның медицина буенча китүе бигрәк тә яхшы, нәселләренә бер табиб булыр, ичмасам. Мондый каты зәхмәтләр заманында үләннәр белән, сулар белән генә дә булмый шул, гыйлемле белгечләр кирәк. Һәм кызының шушы юлдан китәргә ниятләвен ата кеше хуплап каршы алды, зур нәсел аңа үзенең фатихасын бирде.

## Уналтынчы бүлек

Чиләбе медицина училищесына укырга кергәндә, Гөлҗиһан үзендә кан анализларының бик начар икәнлеген белде.

Бу хәбәр аның түбәсенә китереп суккан кебек булды, ул, берни аңламыйча, әле кулындагы кәгазьгә, әле табиб хатынга карады. Өлкән яшьтәге табиб хатын үзе дә бу анализлардан аптырады, монда язылганнар дөрес булса, бу кыз баланың алдагы язмышы инде хәл ителгән иде. Карап торышка, ут чәчеп торган, багалмасы кебек сылу кыз, ә нинди кан. Атом тамгалы. Ягъни аның инде балалары да булмаячак, булса да, алар гарип туарга мөмкиннәр, үзе дә гомер буе бу авырудан җәфаланачак. Хәер, хәзер Коншак тирәсеннән күпләр шундый начар кан белән килә бит.

— Коншактан килдеңме? — дип сорады ул, уйларын раслау өчен.

— Әйе, апа, Татар Караболагыннан мин. Ә сез кайдан белдегез?

— Каның сөйләп тора, сеңелем, каның. Сез аннан барыгыз да тамгалы киләсез бит.

— Нинди тамга? — дип сорады Гөлҗиһан куркып.

Олы яшьтәге татар хатыны озак сөйләп тормады, аңа артыгын әйтергә ярамый иде. Әмма ул бу сөйкемле татар баласын бик кызганды, аңа ярдәм итәсе, аз булса да хәленең нинди булуын сиздерәсе килде.

— Башың әйләнәме? — дип сорады ул, Гөлҗиһанның авыру билгеләрен үзеннән әйттерәсе килеп.

— Әйе. Гел түгел, вакыты-вакыты белән.

— Борының еш каныймы?

— Каный. Колакларымнан да кан киткәне бар. Теге вакытта, Иртәштә завод шартлагач, бик озак авырып яттым мин. Чәчләрем дә коелган иде, аннары яңадан чыкты. Ул вакытта безнең класстан әллә ничә бала үлде, мин чак кына исән калдым.

Әйе, табиб хатын бик яхшы хәтерли ул чакларны. Ул вакытта алар Чиләбегә китергән мәетләрне ярып өлгермиләр иде, туганнары күмеп өлгерми иде. Ә авыл халкы чебен урынына кырылды, аларга нидән авырганнарын да, нидән үлгәннәрен дә әйтергә ярамый иде. Хәтта табиблар да «Маяк» белән, радиация белән бәйле дәүләт серен ачмаска кул куйганнар иде.

— Ә хәзер хәлең ничек, сеңелем? — дип сорады табиб хатын, атомның чираттагы корбанына гаять кызганып карап.

— Хәзер яхшы, апа. Кай вакытта тик торганда хәл бетә бетүен, авыз эче кибә, гел эчәсе килә. Аннан үтә. Безнең бө-

тен авыл шулай авырый, нәрсә икәнен беркем белми. Нәрсә соң миндә, апа?

Табиб хатын аның соравын җавапсыз калдырды. Шактый вакыт Гөлҗиһанга текәлеп карап торганнан соң, кинәт кенә сорап куйды:

— Йөргән егетең бармы, сеңелем?

Гөлҗиһан мондый сорауны көтмәгән иде, бит алмалары кып-кызыл булып чыкты. Нигә аның егете турында сорый икән бу апа, әллә Фәргать турында берәр нәрсә беләме икән?

— Бар иде... — диде ул, ничек җавап бирергә белмичә. — Хәзер юк инде. Хәзергә юк.

— Булмаса, ашыкма, сеңелем, — диде табиб хатын. — Бу кан белән сиңа, гомумән, ашыгып кияүгә чыгарга ярамый.

— Нигә, апа? Канның кияүдә ни катнашы бар кый?! — диде Гөлҗиһан, мишәр үткенлеге белән.

Казан якларыннан килгән татар хатынына аның бу үткенлеге ошады, ахры, ул елмаеп куйды. Бу чая кыз тормышта югалып калырга охшамаган иде, әмма кайбер нәрсәләрне белеп торырга да тиеш. Соңыннан үкенмәс өчен.

— Кияүгә чыгарга мөмкин, сеңелем, — диде ул, Гөлҗиһанның аркасыннан кагып. — Әмма бала табу белән ашыкмаска кирәк.

— Ә нигә? — диде Гөлҗиһан, берни аңламыйча.

— Чөнки бу кан белән аларның авыру туулары мөмкин, — диде табиб хатын, «гарип» дип әйтергә теле әйләнмичә. — Хәер, мондый очракта, гадәттә, бала булмый.

Бу сүзләрне ишеткәч, Гөлҗиһан тынсыз-өнсез калды. Ничек инде ул — бала булмый?! Гөлҗиһан ана була алмый дигән сүз бит инде бу?! Нәселдә булмаганны! Нәрсә сөйли бу Чиләбе табибы?!

— Нишләп минем балам булмасын ди, апа?! Мин саусәламәт бит, кайдан чыгып әйтәсез моны? Безнең нәселдә андый кеше юк, барысында да бер оя бала.

Артыграк әйтеп ташлаганын аңлап, табиб хатын аны юатырга тырышты. Бу авыл баласын шулхәтле кызу, кайнар булыр дип кем уйлаган. Ә үзе турында дөреслекне барыбер белергә тиеш бит инде ул, бер өлешен булса да белергә тиеш. Калганын үзе аңлар, бу анализлар белән әле аңа күп газапланырга туры килер.

— Син медицина училищесына килдең, сеңелем, — диде ул, Гөлҗиһанны тынычландырып. — Тиздән үзең дә күп нәрсәләрне аңларсың. Әмма мин сине кисәтеп куюны кирәк таптым — кияүгә чыксаң да, бала табарга ашыкма. Аларның гарип туулары бар.

Гөлҗиһан ничек итеп табиб бүлмәсеннән атылып чыкканын сизми дә калды. Бу сөйләшүне башкалар ишетмәдеме

икән дигәндәй, тизрәк як-ягына каранды, аның бәхетенә, ишек төбендә берәү дә юк иде. Гөлҗиһан йөгереп урамга чыкты, кешеләргә бәрелә-сугыла, тулай торакка таба йөгерде. Аның тизрәк бүлмәсенә кереп бикләнәсе, бөтен кешедән, хәтта үз-үзеннән качасы килде. Бүген табиб хатын аңа, күзенә карап, үлем карары чыгарган иде.

Озак, бик озак тулай торакның саргайган түшәменә карап ятты Гөлҗиһан.

Аның башында, йөрәгендә, җанында бер генә уй бәргәләнде — аның баласы булмаячак, булса да, гарип туачак. Нигә, нигә алай?! Гөлҗиһанга бит әле нибары унҗиде яшь, аның матурлыгыннан, чаялыгыннан Караболак егетләре телсез кала иде. «Нурыңнан күзем камаша» дип, Фәргать аның йөзенә туры карый алмый иде. Алар бит Фәргать белән өй тулы, итәк тулы балалар үстерү турында хыялланганнар иде! Ничек була соң бу — унҗиде яшеңдә «Синең балаң булмый, булса да, гарип туа» диләр? Имеш, аның канында тамга бар. Нинди тамга ул, кем салган аны Гөлҗиһанга, кайчан салган? Ничек котылырга аңа бу куркыныч тамгадан?

Медицина училищесында укый башлагач кына, Гөлҗиһан эшнең ни дәрәҗәдә җитди икәнлеген аңлады. Аның канында кызыл кан күзәнәкләре кими башлаган, нәтиҗәдә генетик код бозылган, хромосома төзәлмәслек булып үзгәргән иде. Бу исә халык телендә «ак кан» дип аталган кан рагына, ягъни лейкемиягә китерергә мөмкин икән. Боларны белгәч, Гөлҗиһан өнсез калды. Ул тумаган балалары турында уйлап утыра, ә үзенең хәле һаман яшәү белән үлем арасында икән бит әле. Теге вакытта ул могҗиза белән исән калды, ә аның классташлары шушы авырудан китеп барганнар икән бит. Каннары агуланган. Каннары бозылган. Каннары беткән. Авылда кинәт кенә сукыраеп калган, аяк-куллары череп ятучылар да шушы кан авыруыннан икән бит, ә алар нидән чирләгәннәрен, нәрсәдән үлгәннәрен дә белмиләр.

Ә кан нидән шулай кинәт кенә үзгәрә — бу турыда дәреслекләрдә кистереп әйтелмәгән, һаман шул тышкы һәм эчке факторларга кайтарып калдырганнар. Бу бозык каннан ничек котылу юллары да медицина китапларында ачык күрсәтелмәгән — һаман шул режим, дөрес туклану, дөрес яшәү, саф һава, имеш. Иң соңгы очракта даими рәвештә тәнендәге бар авыру канны алыштырып торачаклар икән. Әмма ул тиздән тагы шундыйга әйләнәчәк.

Боларны белгәч, Гөлҗиһан кара кайгыга төште.

Аның тәне буенча авыру, агулы кан ага иде.

Гөлҗиһан үзе ныклап авырмый да кебек, әмма каны тамгалы. Һәм ул кайчан да булса үзен бер сиздерергә мөмкин. Кайчан килеп чыгар бу хәл, кайчан бу мәкерле авыру Гөл-

җиһанны аяктан егар — беркем белми. Шул исәптән Гөлҗиһан үзе дә белми. Шушы мизгелдән аның аяк астыннан җир китте, яшәвенең мәгънәсе калмады. Нәрсә дип яшәргә хәзер бу тормышта, нинди шатлыгы бар аның хәзер? Үлем көтеп, гарип балалар табу өчен яшәргәме? Караболакның иң гүзәл, иң чая кызы Гөлҗиһанны шундый язмыш көтеп торыр дип кем уйлаган?

Эчтән шундый утлар яндырса да, тыштан Гөлҗиһан барыбер сер бирмәде, элеккеге Гөлҗиһан булып калырга тырышты. Ул элеккечә сокланырлык матур, сылу, тырыш иде, группаларында бөтен эшләрне башлап ул йөрде. Тик зур яшькелт күзләрендәге тирән сагышны гына Гөлҗиһан беркая яшерә алмады, аның бөтен җан сыкравы шуларда чагыла иде.

Уку барышында Гөлҗиһан тагы бер тапкыр теге татар табибы белән сөйләшеп карарга булды, чөнки аның кем белән булса да борчуларын уртаклашасы, киңәшләшәсе килә иде. Бүген кайгысын белгән кешенең ярдәме кирәк иде аңа.

— Апа, мин үз авыруымны беләм хәзер, — дип башлады ул сүзен, табиб хатынның күзләренә карап. — Тик нишләргә кирәклеген генә белмим. Нишләргә соң миңа бу авыру белән?

— Яшәргә, сеңелем, — диде табиб хатын, берни булмагандай. — Мәгънәле, матур итеп яшәргә. Үлем көтеп утырмаска.

Бу сүзләрдән Гөлҗиһан аптырап китте.

Әллә көлә инде аннан бу табиб апа? Үзенең нинди хәлдә икәнлеген белә торып, ничек матур итеп яши алсын инде хәзер Гөлҗиһан?

— Үземнең гомерлек чирле икәнемне белә торып, ничек онытылып яшәп булсын инде ул, апа?! — диде ул, күз яшьләрен көчкә тыеп.

Табиб урыныннан торды да Гөлҗиһан янына килеп басты. Ул аны кулларыннан тотып, тәрәзә каршына алып килде.

— Әнә, кара әле, сеңелем, урамга, — диде ул, Гөлҗиһанны иңнәреннән кочып. — Әнә, култык таягына таянып, бер аяксыз кеше килә — яши бит! Әнә кара күзлектән дөм сукыр хатын атлый — ул да яши, әле янында кечкенә баласы. Әнә атлаган саен гарипләр — алар да яшиләр, үз тиңнәре белән гаилә коралар, балалар үстерәләр. Тормыштан ямь таба беләләр. Алар белән чагыштырганда, синең бөтен нәрсәң дә бар — яшьлегең, чибәрлегең, акылың, гыйлемең. Иң мөһиме — дүрт саның исән, күзләрең күрә, колакларың ишетә. Нәрсә, бу бәхет түгелмени?

— Ә каным? — дип бүлдерде аны Гөлҗиһан. — Мондый кан белән мин дә шундый хәлгә калырга мөмкин бит. Теләсә кайсы вакытта берәр хәл килеп чыгарга мөмкин. Шуны белә торып, ничек тыныч кына яшәргә була, апа?

— Ә син ул турыда уйлама, — диде табиб хатын, Гөлҗиһанны каршына утырты. — Бу тирәдә хәзер ике кешенең берсендә шундый кан, шундый авыру. Үзләре бу хакта беләмиләр дә. Син булачак медик булганга гына әйттем бу хакта, авылда яшәсәң, әле һаман белмәс идең.

— Үлеп киткәнчеме?

— Анысы инде, сеңелем, Алла кулында. Яшәргә теләсәң — яшәрсең, үләргә теләсәң — үләсең инде. Мин үзем егерме ел инде шундый кан белән яшим менә.

Гаҗәпләнүдән Гөлҗиһан сүзен әйтә алмый торды. Һәрвакыт елмаеп йөргән мөлаем, җыйнак бу татар табибы турында авыру дип һичкем әйтмәс. Ә аңа кайдан килде икән бу куркыныч чир, ул бу якларныкы да түгел икән бит.

— Безнең авылда, Иртәштә шартлагач, халык авырый башлады, ә сез нидән шулай булдыгыз? — дип сорады Гөлҗиһан, үзенә хас турылык белән.

— Мин бу якларда күптән эшлим инде, сеңелем, — диде табиб хатын, бик ачылып китмичә генә. — Эләгәсе миңа да эләккәндер. Бер һава сулыйбыз, бер су эчәбез бит.

Ул үзенең ачылу белән Сөнкүл больницасында эшләвен, радиациянең эчендә йөзүен бу яшь кызга әйтеп тормады. Ул аңа болай да артыграк ычкындырган иде инде. Анда ул үзенең яшьлеген күргән кебек булды, бу якларга эшкә җибәргәндә, ул да шулай ут чәчеп тора иде. Аннан Иртәш, Сөнкүл бу Казан кызыннан бөтенесен суырды, бөтенесен тартып алды — яшьлеген дә, сәламәтлеген дә, туасы балаларын да. Бүгенге көндә аның гаиләсе дә, балалары да юк, булмады да. Мондый кан белән бу татар кызын да шундый язмыш көткәнгә, ул аны бераз булса да кисәтәсе, мондый тормышка әзерлисе килде.

— Син авыруың турында уйлама, сеңелем, — диде ул аңа, чәчләреннән сыйпап. — Әлбәттә, Чиләбе якларыннан башка җиргә күчеп карарга да була, әмма бу тамга, кая барсаң да, синең белән китәчәк. Син шуның белән яшәргә өйрән. Иң мөһиме — каныңны кыздырма, ягъни борчылмаска тырыш, нервларыңны сакла. Үлем турында уйлап йөрмә, тәкъдиреңә кайчан язылган — ул шунда киләчәк, шулай бит?

— Шулай кый... — диде Гөлҗиһан уйчан гына. — Безнең Таһирҗан бабай да шулай ди. Әҗәлне чакырып китерә алмассың, килсә, куып җибәрә алмассың ди.

— Бабаң бик дөрес әйтә, — диде табиб хатын. — Безнең якларда да шулай диләр. Син кайгырма, сеңелем, хәзер медицина көчле, бәлки әле бу авырулардан да дәва табарлар. Үзең шушы юлдан китеп тә бик дөрес эшләгәнсең, сәламәтлегең үз кулыңда булачак. Башкаларга да ярдәм итәрсең, Алла боерса.

Аның янында Гөлҗиһан шактый тынычланып чыкты.

Әйе шул, кан начар булу — ул әле үлем дигән сүз түгел бит. Әнә бу табиб апа да: «Егерме ел шулай яшим», — ди бит. «Ике кешенең берсендә хәзер шушы авыру», — ди. Ә алар авылында, Караболакта, бөтен кешедә шушы авыру инде болай булгач. Үзләре бу хакта бөтенләй белмиләр дә. «Бәлки, белмәүләре яхшыдыр да, — дип уйлады Гөлҗиһан, авылдашларын күз алдына китереп. — Белеп нәрсә эшли алырлар иде?»

Табиб аңа борчылмаска, кызмаска кушты, «Ни булса да, кайнарланма, гел салкын канлы булырга тырыш», — диде. Ә ул Фәргать турында уйлауга, ялкынланып яна башлый. Бу хәл Гөлҗиһанның үзеннән тормый бит, аның йөрәге, күңеле шулай өзгәләнә. Оныта алмый ул Фәргатьне, онытырга теләми дә. Гөлҗиһан башка егетләргә күтәрелеп тә карый алмый, үзен гел Фәргатьнең ярәшелгән кызы итеп хис итә. Бу чынлап та шулай бит, алар ярәшкән егет белән кыз иделәр. Бөтен Караболак аларның туйларын көтә иде. Ә Фәргать Иртәштән бер елдан да кайтмады, икенче елны да күренмәде, өченчесендә дә барлыгын хәбәр итмәде. Әниләренә телеграммалар җибәреп, телефоннан сөйләшеп тора икән, әмма алар янына да бер тапкыр да кайтып карамаган. Исәнлеккә — исән, әмма кайтмый, Миасска да, Караболакка да. Гөлҗиһанга ник бер хат-хәбәре булсын?! Әйтерсең лә ул гомерендә дә Гөлҗиһан дигән кызны белмәгән, сөймәгән, өйләнергә вәгъдә бирмәгән. Димәк, ул Гөлҗиһанны онытКАН, тормышыннан сызып ташлаган.

Ә Гөлҗиһан аны бер генә минутка да исеннән чыгара алмый.

Кич ятса да, иртән торса да күз алдында, елмаеп, күрше егете Фәргать басып тора. Аның кебек матур елмая торган тагы берәр кеше бармы икән дөньяда? Фәргать елмайганда, аның бит урталары балаларныкы кебек, уймакланып керә, коңгырт күзләреннән нур түгелә. Аның кара чәчләре, дулкын-дулкын булып бөдрәләнеп, киң ак маңгаена төшеп тора. Пәһлевандай гәүдәсеннән, киң җилкәләреннән көч-гайрәт бөркелә. Андый матур һәм батыр кешене Гөлҗиһан гомерендә дә очратканы булмады һәм очратмас та инде. Фәргатькә ни генә булса да, ул мәңге Гөлҗиһанның хыялында яшәячәк.

Менә алар аның хыялларында ак кар баскан Караболак урамнары буйлап йөриләр, балалар кебек, кочаклашып, чана шуалар. Менә алар, бергәләп, Караболак болыныннан җиләк җыялар, Биташ чишмәсеннән су эчәләр, мәгарәдә качыш уйныйлар. Менә алар, җитәкләшеп, булачак нигезләренә кайталар. Ишегалды тулы яшел чирәм. Шул чирәмдә Фәргать белән Гөлҗиһанның балалары уйнап йөри. Тукта. Тукта, Гөлҗиһанның балалары булмаячак бит. Булса да, алар гарип

туарга мөмкин. Димәк, Фәргатьнең кайтмавы, аларның туйлары булмыйча калу, бәлки, хәерлегә булгандыр?.. Фәргатьнең күзенә ничек карар иде Гөлҗиһан, әгәр ана була алмаса? Бу турыда уйлагач, Гөлҗиһанның йөрәге өзелеп төшә язды, чигәсендә кан шаулый башлады. Әгәр гарип балалар тапкан булса? Ул бит Фәргатьне гомергә бәхетсез иткән булыр иде! Димәк, эшнең шушылай бетүе аларның икесе өчен дә яхшы булган. Таһирҗан бабай әйткәнчә, ни булса да, хәерлегә булган?!

Таһирҗан бабасы исенә төшүгә, Гөлҗиһан җиңел сулап куйды, җаны тынычланды, каны чигәсендә шауламый башлады. Менә кем белән киңәшергә кирәк иде аңа. Ул әтиәнисенә, әби-бабасына үзенең авыруы турында берни әйтмәде, үз хәлен алардан яшерде. Ә нигә аларны борчырга, хәвефкә салырга? Табиб апа дөрес әйтә, бу турыда, гомумән, уйламаска кирәк. Авыртулары әлегә түзәрлек, хәзер Гөлҗиһан даруларда да рәт белә, үз организмын да яхшы өйрәнде. Башы әйләнеп, чигәләре шаулый башласа, моның нинди хәбәр икәнлеген шунда ук аңлый, бөтенләй егылмас өчен хәстәренә керешә. Шуңа күрә өйдәгеләр аның нинди куркыныч авырудан газапланганын сизмиләр дә, белмиләр дә. Алар барысы да Гөлҗиһанга тормыш терәге, киләчәктә ярдәмче буларак, зур өметләр белән карыйлар. Ә менә хәзер Гөлҗиһанның үзенә ярдәм, төпле киңәш кирәк. Юк, авыру мәсьәләсендә түгел, алдагы тормышы буенча Гөлҗиһанга төпле олылар сүзе кирәк...

Ул киләсе елга укуын тәмамлый.

Алга таба кая барсын, укуын дәвам итсенме, эшкә керсенме? Эшкә керә икән, Чиләбедә калсынмы, әллә бу тирәләрдән еракка качсынмы? Әллә инде шушы авыру-зәхмәт арасына, Караболак якларына эшләргә кайтсынмы? Фәргатьне көтсенме, әллә инде аның белән араны мәңгегә өзсенме, үз тормышы турында уйласынмы? Болар хакында ул ачылып, сәбәпләрен әйтеп, әти-әнисенә сөйли алмый, ә Таһирҗан бабайга сыя. Гөлҗиһанны бары тик ул гына аңлаячак һәм дөрес киңәшен дә бирәчәк.

Һәм ул Таһирҗан бабасына ачылырга булды...

## Унҗиденче бүлек

Бу юлы Караболакка җәйге ялга Гөлҗиһан зур планнар һәм ниятләр белән кайтты. Аңа алга таба язмышын хәл итәргә кирәк иде. Әмма Гөлҗиһанны авылда берсеннән-берсе авыр, борчулы хәбәрләр көтеп тора иде. Кайтып керүенә, ул әтисен урын өстендә күрде. Өрлектәй таза нык ир, аяксыз калып, урын өстенә яткан. Аның гәүдәсе дә шешенеп киткән,

ул, караватына сыя алмыйча, кисеп аударган имән кебек, авып ята.

— Әти, нәрсә булды сиңа? — дип, Гөлҗиһан аның янына ташланды.

Ата кеше иң авыр вакытта кызының кайтып керүенә чын күңеленнән куанды, әйтерсең лә коткаручысы кайткан иде. Ул хәтта сызлануларын да онытып торган кебек булды, әкрен генә торып утырырга тырышты.

— Менә... аяклар сызлый башлады әле, кызым, — диде ул, үз хәленә үзе уңайсызлангандай. — Бөтенләй йөрми башладылар.

— Нигә башта ук миңа хәбәр итмәдегез соң? — дип өзгәләнде Гөлҗиһан, нишләргә белмичә. — Чиләбедә яхшы табибларга күрсәткән булыр идек.

— Коншакта булдым мин, — диде әтисе сүрән генә. — Ревматизм, шуңа сызлый, диделәр... Кайткач, бөтенләй аяксыз калдым менә...

— Анализларың ничек соң? — дип сорады Гөлҗиһан, сагаеп калып.

— Алары Коншакта калды инде, бирмәделәр. Болай... куркыныч түгел, общий авыру, диделәр. Хәзер авылда мондый авырулар күп бит инде, кызым. Ике йортның берсендә кайсы аяксыз, кайсы кулсыз дигәндәй... Караболак халкының шулай кырылуына Коншакта ияләнеп беткәннәр инде, «общий авыру» диләр дә, кәгазь тоттырып, кайтарып җибәрәләр. Аннан кеше тиз арада зиратка күчә. Бишенче зиратны башладык бит инде, әйтергә генә җиңел.

Гөлҗиһан икенче көнне үк Коншакка чыгып китте. Әтисенең анализларын аның үз күзләре белән күрәсе, чын дөресен беләсе килде. Әмма Коншакта аңа анализларны күрсәтергә ашыкмадылар. «Анда ревматизм, бу яшьтә була торган хәл инде ул» дип әйтүдән узмадылар. Аларның бу битараф җавабы Гөлҗиһанны гаҗәпкә калдырды. Нинди яшь ди ул, әтисенә бит әле илле дә юк! Аларның нәселе туксанга, йөзгә хәтле авыртуның ни икәнен белмәгән нык нәсел бит! Нигә имән кебек ир кинәт кенә аяксыз калган әле? Аның анализлары ни күрсәтә?

Йөри торгач, әтисенең анализларын тапты, соратып ала алды Гөлҗиһан. Аларга күз ташлау белән, аның аяк астында җир чайкалып куйды — әтисендә, Гөлҗиһандагы кебек, кан авыруы иде. Һәм шуның өстенә шикәр чире, ягъни диабет. Ә ул, чыннан да, ашыгыч чара күрмәсәң, аяк-кулларның черен коруына китерергә мөмкин. Бу исә кешене үлемгә китерә. Ә аны ревматизм дип, «общий авыру» дип ялганлап, авылга үләргә кайтарып җибәргәннәр...

Гөлҗиһан Коншак табибларын елый-елый сүкте, аларны

наданлыкта, рәхимсезлектә гаепләде, әтисен кичекмәстән юллама белән, Чиләбе больницасына җибәрүләрен таләп итте. Шулай шаулап, бүлмәдән бүлмәгә йөри торгач, баш табиб рөхсәте белән, Гөлҗиһанның әтисен Чиләбе ФИБына җибәрергә булдылар, моның өчен хәтта районнан машина да бирделәр. Иртәгә иртүк юлга чыгарга ниятләп, Гөлҗиһан яңадан Караболакка кайтып китте. Өйдәгеләр бу хәбәрне өметләнеп кабул иттеләр, чөнки авылда ятып, Нәбиулланың үлеп китүе дә бар иде.

Бу кайтуында Гөлҗиһан кайгылы хәбәрләрне күп ишетте. Авыл халкы күпләп үлә, чебен урынына кырыла башлаган. Гөлҗиһан белән бер класста укыган Мәйсәрә, Саҗидә, Мәрзия үлеп киткәннәр, Әгъзамны, читтән алып кайтып, Караболакка күмгәннәр. Алар белән теге вакытта кырда эшләгән укытучы абыйлары да үлгән, тагы берничә укытучы кинәт кенә үлеп киткән.

Боларны ишеткәч, Гөлҗиһан өйдәгеләрдән яшеренеп кенә бик елады. Ул бу укучыларны, укытучыларны һәрберсен тере итеп күз алдына китерде, күңеле мондый зур югалту белән килешәсе килмәде. Алар барысы да аның иптәшләре, авылдашлары, остазлары иде. Хәзер Караболакның бишенче зиратында яталар. Әле яши дә башламаган килеш. Гөлҗиһан да шулар арасында булырга мөмкин иде бит. Ничек котылырга соң бу афәттән, ничек Караболакны бу бәладән коткарырга? Югыйсә тиздән бөтен авыл зиратка күчеп бетәчәк бит.

Гөлҗиһан әтисенә авыртуны баса торган көчле дарулар бирде, укол ясады, аның хәле бераз җиңеләйгәч, Таһирҗан бабаларына барып кайтырга булды. Гөлҗиһанның бабасы белән киңәшәсе нәрсәләре бар иде.

Таһирҗан бабасы намаз укый иде, Гөлҗиһан, ишек яңагына сөялеп, аның укып бетергәнен көтеп торды. «Әле ярый бу картлар нык, — дип уйлады ул сөенеп. — Аның әбибабасы да, Таһирҗан бабай да авыруның ни икәнен белмиләр, Аллага шөкер. Әкрен генә үзләренчә яшәп яталар. Зиратка яшьләр күчә...»

— Үзем дә сезгә барып килергә тора идем әле, кызым, — диде Таһирҗан карт, намазлыгын җыя-җыя. — Атаң авырып китте бит менә. Һәр көн менеп, үземчә өшкереп тә төшәм. Хәле бераз җиңеләйгән кебек була да тагы сызлана башлый. Авыруның катысы эләккән атаңа, кызым, катысы, ычкындырырга исәбе юк.

— Әтине иртәгә Чиләбе больницасына алып китәбез, Таһирҗан бабай, — диде Гөлҗиһан. — Бәлки, операция ясатырга да кирәк булыр әле.

— Шулай укмы, кызым? Бәлки, шулай яхшырак та булыр. Алла биргән гомерен аягында йөреп уздырсын инде.

— Синнән яшереп булмый инде, Таһирҗан бабай, әтинең авыруы начар, — диде Гөлҗиһан, керфегендәге яшьләрен сөртеп. — Миндә дә шул авыру — начар кан. Дәвалап та бетми торган ул.

Таһирҗан карт шактый вакыт дәшмичә, уйланып утырды. Ул болар хакында Гөлҗиһан әйтмәсә дә белә иде.

— Күп кешедә хәзер шундый кан, кызым, — диде ул, уйчан гына. — Тамгалы кан. Моны халык үзе белми генә.

— Элек алай булмаган бит, Таһирҗан бабай! Син үзең сөйли идең бит, безнең авылда Алыплар нәселе яши дип. Бу Иртәш шартлагач шулай булдымы соң?

— Бу хәлләр тагы да иртәрәк башланды, кызым, Иртәштә шул атом дигәннәрен эшли башлауга һавага агуы таралды. Шул суга, туфракка сеңде, күккә таралды. Бу тирәдән йөзәр, хәтта меңәр чакрым ераклыктагы халык шул афәттән зыян күреп яши.

— Нидер эшләргә кирәк бит инде, Таһирҗан бабай! — диде Гөлҗиһан, кыза төшеп. — Бөтен авыл үлеп бетә бит инде, әнә бишенче зиратны ачкансыз! Бәлки, безгә моннан күчәргә кирәк булгандыр?

— Кайда күчсәң дә, тамга салынган инде, кызым, — диде Таһирҗан карт, сабыр гына. — Бөтен илендә, дөньясында шушы хәл. Кеше үз башына гыйфритне шешәдән чыгарды. Бүген безнекеләр зиратка күчә, иртәгә чират башкаларга да җитәчәк. Әмма алар бу хакта белмиләр, уйламыйлар әле.

— Юк, бабай, юк! — диде Гөлҗиһан. — Болай бөтен авыл белән үлем көтеп утырырга ярамый! Нәрсә булган бу Караболакка? Нидер эшләргә кирәк бит инде!

Таһирҗан карт оныгын тынычландырырга ашыкты, чөнки аңа борчылырга ярамаганын белә иде ул.

— Без, соңгарак калып булса да, эзләнергә тотындык, кызым, — диде ул. — Коншактан, Чиләбедән табиблар чакыртып торабыз, бу чирләрнең нидән икәнен, ничек дәваланырга кирәклеген сорыйбыз. Алар дөресен әйтми, әлбәттә, «гомуми авыру» диләр дә, берәр төймә каптырып китәләр. Бәлки, үзләре дә белмидер, бәлки, бу хакта әйтергә ярамыйдыр. Әмма бу зәхмәтнең Иртәш белән бәйләнгәнлеге билгеле безгә. Хәбибулла абыең да үлгән вакытта «атом» дип үлде бит. Димәк, аның авыруы да шул атом зәхмәтеннән булган. Ә ул — дәүләт сере, аның хакында соратмыйлар да, сорасаң да әйтмиләр. Халык аптырашта хәзер, кая барып төртелергә белгән юк.

— Әмма авылда авырмаучылар да бар бит! — диде Гөлҗиһан, бу ачышыннан үзе дә аптырап. — Карт як чирләми, менә сез дә бирешмисез карттай-картнәйләр белән. Димәк, бу чир сайлап кына ябыша, сайлап кына алып китә?

— Анысы Аллаһ кулында инде, кызым, — диде Таһирҗан карт, сөйләшүнең шушы якка кереп китүенә куанып.

Чөнки ул белә — бу авыруга бирешмәгән карт-коры барысы да диндәге, намазлы кешеләр. Алар Караболак суына якын килмиләр, ерак булса да, Биташ чишмәсенә йөриләр. Алар яшьләр бик тиз ияләнгән харам ризыкларга, кибет колбасаларына кагылып та карамыйлар, хәләл ит белән генә тукланалар. Кибетләрдә киштә-киштә аракы тора, мәҗлесләрдә хәзер өстәл-өстәл аракы, ә олы як моның нәрсә икәнлеген белмәде бит.

— Караболак халкы диннән чыгып бара, кызым, диннән, — диде ул, зур үкенеч белән. — Менә шуңа күрә зур сынауларга дучар булдык инде, атом ул сәбәпче генә адәм өчен. Динсез, Алласыз яшәгән еллар өчен газабын күрә халык. Ураза вакытында мәктәпләрдә балаларның авызларын көчләп ачтырган укытучылар барысы да китеп бетте инде.

Бабасының бу сүзләреннән Гөлҗиһанга бик куркыныч булып китте. Мәсьәләнең бу ягын ул бөтенләй уйламаган иде, бабасы шундый нәтиҗәгә килер дип көтмәгән иде. Димәк, бу авырулары Гөлҗиһан өчен дә сынау? Сынау һәм җәза? Ә нәрсә өчен? Гөлҗиһан бу дөньяда беркемгә дә бернинди начарлык эшләмәде бит, ул әле яши генә башлады, ә авырулары инде бугаздан ала. Димәк, эш Гөлҗиһан уйлаганга караганда да катлаулырак икән. Бу хәлләрдән табиблар ярдәме белән генә дә котылып булмаска мөмкин икән. Ә Гөлҗиһанның бу хакта уйлаганы да булмады. Аңа Таһирҗан бабасы алдында уңайсыз булып китте. Теге вакытта ул аңа күпме догалар өйрәткән иде бит, аны аякка бастыру өчен күпме тырышкан иде, күпме Биташ суы эчергән иде. Чиләбегә китте дә Гөлҗиһан, шуларның барысын да онытты. Аны үз кайгылары, борчу-мәшәкатьләре басып китте.

— Суны һаман Биташтан эчәсеңме әле, бабай? — диде ул, кечкенә вакытларын исенә төшереп.

— Шуннан, кызым, шуннан. Әле бүген дә барып кайтырга тора идем, атаңа да өшкереп алым менермен дип уйлаган идем.

— Алайса, үзем генә барып кайтыйм? — диде Гөлҗиһан, Таһирҗан бабасы белән әле сүзе бетмәсә дә. — Үземнең дә күптән күрәсем килә иде Биташны, бераз зәңгәр балчык та алырмын.

Таһирҗан картның онытын болай гына чыгарып җибәрәсе килми иде, чөнки аның Гөлҗиһанга әйтәсе бик җитди сүзе бар иде. Ул онытын җәйгә озаккарак кайтыр дип көткән иде, әйтер сүзе өчен иркенрәк вакыт көткән иде. Ә вакыт бөтенләй булмаска охшаган, әнә иртәгә үк атасы белән Чиләбегә чыгып китәргә торалар. Шуңа күрә ул Биташка Гөлҗи-

һан белән бергә барып кайтырга уйлады, аңа әйтер сүзен дә шунда әйтергә булды. Һәм алар, тиз генә җыенып, авыл башындагы Биташка чыгып киттеләр.

Гөлҗиһан Караболакны бик-бик сагынган иде.

Чиләбедә күпме яшәсә дә, ул аңа ияләнә алмады, биек таш йортларыннан җәй көне дә туңды, өшеде. Суын да яратмады ул Чиләбенең, андагы хлор тәменә ияләнә алмады, шәһәр читләрендә колонка күрсә, авылны искә төшереп, йотылып эчә иде. Туктаусыз ыгы-зыгысын, шау-шуын да яратмады Гөлҗиһан Чиләбенең. Шәһәрдә аның бердәнбер юанычы — укуы иде, гыйлем аны тулысынча үзенә йотты. Урамда татарлар очраса бик сөенә иде Гөлҗиһан, аларның хәтта ияреп артларыннан бара иде. Казаннан килгән концертларны да йотылып тыңлый иде ул, аңа Уралның аръягы дөнья чите булып тоела иде. Һәм аларның да, Гөлҗиһан кебек, татарча сөйләшүләре, җырлаулары аңа бер могҗиза булып күренә иде.

Әмма барыбер Караболакка җитми иде.

Җире-суы агуланган булса да, авыл башын тоташ зиратлар чорнап алса да, дөньядагы бер генә урын да Гөлҗиһанга Караболак кебек якын һәм кадерле булмас иде. Юк, булмас иде. Туган авылында бер генә йорт, бер генә кеше калса да, хәтта беркем яшәмәсә дә, җанына җылы эзләп, Гөлҗиһан барыбер бирегә кайтып егылыр иде. Менә ни өчен Таһирҗан бабасы күченүгә атлыгып тормаган, әти-әнисе, әби-бабалары шушы фаҗигале Караболакта торып калганнар. Аларның Гөлҗиһанны, балаларын туган туфраксыз, туган нигезсез калдырасылары килмәгән.

Ә Караболак элеккеге тормышы белән мәш килеп яшәп ята, әйтерсең лә аның өстеннән атом афәте үтмәгән, әйтерсең ярты авыл зиратка күчеп бетмәгән. Исән кеше яшәү турында уйлый шул, Караболак халкы бигрәк тә. Зарланып, мескенләнеп елап утырса, Караболак буламыни инде ул? Караболак елгасын яр буйлатып чорнап алган тимерчыбыклар да инде күптән куе үлән арасында калган, халык кайдан теләсә, шуннан йөри. Суга төшә, су ала. Елгада бала-чага, малай-шалай чупырдый, каз-үрдәкләр йөзеп йөри, яр буендагы үзәнлектә бозаулар арканланган. Нәкъ Гөлҗиһан кечкенә чактагы кебек, барысы да үз урынына кайткан. Гөлҗиһан әле Караболакның кораллы сакчылар тарафыннан сакланган чакларын да яхшы хәтерли. Ак халатлы, битлек кигән кешеләрнең коеларны җимереп йөрүе исендә. Аннан яңадан барысын да рөхсәт иттеләр. Халык та, сакчылар китүгә, елга буендагы тимерчыбыкларны алып ташлады да суын файдалана башлады. Гөлҗиһан үзе дә әби-бабалары күрмәгәндә, Караболак суына чумып чыгарга ярата иде. Ә җәй көне эсседә кая барасың?

— Халык һаман Караболак суын файдалана икән, — диде ул, елга ягына борылып карый-карый.

— Караболакның суы начарланды, кызым, аны халык та белә, — диде Таһирҗан бабасы. — Әмма ишле гаиләләр кая барсын, мал-туарга суны Биташтан ташып эчереп булмый бит. Мин үзем чишмәгә йөрим йөрүен, әби-бабаң да Биташтан эчәргә тырышалар. Әмма сездә дә мал-туарга суны Караболактан ташыйлар. Шуларның итен бөтен авыл ашый, сөтен эчә. Бер җирдә яшәгәч, барысы да уртак инде аның, кызым, качам дисәң дә, котылып булмый.

Шулай сөйләшә-сөйләшә, Караболак елгасы башланган Алабуга сазлыкларын да үттеләр, бер читтә җимерек Урыс Караболагы авылы урыны утырып калды. Анда эшләгән көннәрен Гөлҗиһан әле һаман онытмый, ул анда үлеп беткән иде бит инде. Әле ярый янында әлеге дә баягы һаман шул Таһирҗан бабай булган, аңа барып әйтергә классташы Рәшидә булган.

— Рәшидә ничек, Таһирҗан бабай, күренгәне бармы? — дип сорады ул бабасыннан.

— Ул инде тәмам җиңеләеп бетте, кызым, — диде бабасы. — Каты авыруы шулай башына бәрде, ахры, бахырның. Үзе болай әдәпсезләнеп йөрми йөрүен, үзенчә сөйләшеп кенә йөри. Гөлҗиһан брач булып кайта да мине терелтә, ди икән...

Бу сүзләрне ишеткәч, Гөлҗиһанның йөрәге сулкылдап куйды. Ничек ярдәм итәргә соң Рәшидәгә, аңа ярдәм итеп буламы икән инде?

— Теге вакытта аны Чиләбедән килгән табиблар карап йөргәннәр иде бит, булмый, дип киттеләр. Анда-монда алып барганнары юктыр бит тагы, бабай?

— И кызым, кем йөрсен инде аның артыннан? — диде бабасы. — Әнисе үлде, әтисе үлем көтеп ята, шул исән туганнары карап тора инде, аларга рәхмәт. Тиләләр йортына бирергә кызганалар, безнең авылда андый гадәт юк бит ул. Кешегә бер зыян да юк бит аннан, хәзер авылда Рәшидә кебекләр шактый инде, кызым. Тумыштан шундый булып туалар.

Алар теләсәләр дә, теләмәсәләр дә, сүз һаман шул авыруларга барып терәлә иде. Шактый вакыт тын гына, һәркем үзенекен уйлап барды. Әтисен больницага салуга, Караболакка кайткач, Гөлҗиһан Рәшидә янына барып килер. Ярдәм итә алмаса да, хәлен белер, әнә бит ул һаман аны көтеп ята икән. Ул элек тә гел Гөлҗиһан тирәсендә була иде шул, кем кыерсытса да, аның янына йөгереп килә иде.

Гөлҗиһан үзенең хәлен Рәшидәнеке белән чагыштырып карады да тетрәнеп китте. Йа Раббым, Гөлҗиһанның хәле

түзәрлек икән бит әле, ул үз акылында, үз аягында, укып йөри, башкаларга ярдәм итә ала. Ә Рәшидә нинди хәлдә менә хәзер. Югыйсә алар бер класста укыдылар, бер кырда эшләделәр, бер суны эчтеләр, бер авылда үстеләр бит. Гыйбрәтләнсәң, гыйбрәтләнер нәрсәләр күп монда. Аның уйларын сизгәндәй, Таһирҗан карт та әйтеп куйды:

— Әйе, кызым. Күккә карап фикер йөрт, җиргә карап шөкер ит, дигән борынгылар. Һәрнәрсә чагыштырганда күренә шул. Бу дөньяда гыйбрәт алыр нәрсәләр күп, бик күп…

Кояш кичке якка борылса да, әле көн эссесе сүрелмәгән иде.

Дөньяда берни дә үзгәрмәгән — нәкъ Гөлҗиһан кечкенә чактагы кебек. Баш очында меңләгән бөҗәк, кош-корт гөжләп, гүләп тора, һәрберсенең ашыгыч үз эше бар. Әнә бик ерактан, җәйге рәшә арасында тибрәнеп, Урал таулары күренеп тора. Бик ярата Гөлҗиһан шул Урал тауларын, әллә Фәргатьнең балачагы, яшьлеге шунда үткәнгә, бу таулар аңа аерата якын. Өйләнешкәч, алар Фәргать белән Урал тауларына сәяхәт итәргә уйлаганнар иде. Фәргать Миасс тирәсендә әллә нинди борынгы тау куышлары, серле, төпсез күлләр барлыгын әйткән иде. Имеш, анда да заманында Алып кешеләре яшәгән икән, алар Туфан суыннан шунда качып исән калганнар, ди. Ул якта халык шулай сөйли икән. Аннан ул Алып кешеләре менә шушы Аллакүл, ягъни Биташ буйларына килеп урнашканнар, Гөлҗиһаннар авылын да алар төзеп калдырган. Бу хакта аңа Таһирҗан бабасы да күп тапкырлар сөйләгән иде бит.

Гөлҗиһаннар авылын үткәч, Караболак елгасы Зәбир авылы янында Тимеряз елгасына коя, аннан Сәнәргә барып төшә. Урыслар Сәнәрне «Синар» диләр, ул карталарга да шулай язылган. Бабасының әйтүе буенча, элек Караболак белән Сәнәр елгалары кушылган урында, ике арада халык алтын юган. Димәк, бу туфракларда, бу тауларда алтын да бар дигән сүз. Бәлки, ул скиф курганнарыннан су белән юылып чыккан алтын-көмеш булгандыр. Шул алтын-көмешләрен алып, Сәнәр Исәткә, Исәт Тубылга, Иртәшкә барып кушыла, аннан Караболак сулары Обь елгасына ук барып төшә. Аннан — Төньяк Боз океаны. Фәргатьнең, Караболак суы буйлап, шул якларга ук барып кайтасы килә иде. Күпме хыяллары чәлпәрәмә килде, тормышка ашмыйча калды. Караболак суы да хәзер инде алтын-көмештән тормый, аннан хәзер Төньяк Боз океанына кадәр агу ага.

Ә Аллакүл-Биташ бу афәттән бераз читтәрәк, тау араларына урнашкан, шуңа күрә илгә килгән бәла аңа тәэсир итмәгән кебек. Бала чакта Гөлҗиһан авыл балалары белән бергә еш килә иде, алар караңгы төшкәнче тау куышларында

качыш уйныйлар иде. Алып Адәм басып гыйбадәт кылган ташны Гөлҗиһан беркемгә дә бирми иде, ул бары тик аныкы гына иде. Ул малайларның да инде күбесе юк.

— Бу күлне күктән иңгән таш урынында барлыкка килгән дип сөйлиләр иде, — диде Таһирҗан бабасы, Биташның аяк очына килеп утырып. — Элек халык бу тирәгә намаз укырга, теләк теләргә йөргән, хәзер юк инде.

— Бабай, хәтерлисеңме, син миңа бередә бер шигырь өйрәткән идең? Мин шуны мәктәптә укыгач, чак кына куып чыгармадылар, хәтерлисеңме?

Таһирҗан карт елмаеп куйды. Булган иде шул андый хәл. Соңыннан Хәбирә килен бераз үпкәләп тә йөрде, балага әллә нәрсәләр өйрәткәнсең дип. Ә ул Казанда укып йөргәндә ишеткән иде бит бу шигырьне. Аннан мәрткә киткәч, яңадан исенә төште.

— Әйбәт шигырь иде ул, кызым. Шәп сөйли идең син аны кечкенә вакытта. Хәзер оныткансыңдыр инде?

— Син нәрсә, бабай, шундый шигырьне онытам диме инде? Мин аны Чиләбедә редакциягә дә илтеп биргән идем әле, басмадылар, безнең көннәргә туры килми, фикере искергән дип. Бер дә искермәгән, менә, тыңла әле, бабай!

Әй, милләтнең сылу балалары!
Дөнья тетрәткән Хан бабалары!
Ханыңны — барча гаскәреңне
Дошманнар узып китте…
Куәтле чаклар кайларга китте?
Җыелыгыз, түгелгән күз яшьләр!
Атлагыз алга! Күрсен көндәшләр.
Чәч гайрәт! Баһадир бәһале Җан Син!
Фикерең бер мәмләкәт, син аңа җансың.
Гайрәтле бер милләт җитәкчесе бит без,
Ялкынлы милләтнең аркасы бит без!
Яшәде дөньяда баһадир бабаң,
Диде ул: якты тормышта яшәсен балам!
Яшә син дөньяда, ал гыйлем кулга,
Тугры юл, карама уңга да сулга!
Дөньяны гизеп йөр, бар алга таба,
Гизде бит дөньяны һәм Чыңгыз бабаң!
Арма син! Алдан бар, дошманнан калма!
Алга бас, татар, алга бас, алга!

Таһирҗан карт оныгына сокланып карап торды, ул бер дә үзгәрмәгән иде. Ә аның тәнендә һәм җанында нинди авырулар, газаплы сызланулар барлыгын бик яхшы белә бит Таһирҗан карт. Гөлҗиһан өчен гаять кайгылы хәбәр аның үзендә дә бар, әмма ул аны әйтергә җай таба алмый.

— Бу — безнең татар милләте турында шигырь, кызым, онытма син аны, — диде Таһирҗан карт, аны тыңлап бетергәч. — Менә күрерсең, әле заманалар үзгәрер. Милләт ту-

рында һәр дөрес сүз алтын бәясенә торыр. Халыкны уятыр өчен, шул вакытта менә бу шигырь дә кирәк булыр.

Шулай сөйләнә-сөйләнә, Таһирҗан карт алып килгән савытларына чишмәдән су тутыра башлады. Гөлҗиһан да биткулларын юды, учлап-учлап боздай салкын су эчте, бөтен тәне-җаны рәхәтләнеп, сафланып киткән кебек булды. Ул, бала вакыттагы кебек, аякларын күл суына тыгып утырды, бер мизгелгә булса да, дөнья кайгылары онытылып торды. Гөлҗиһан, иелеп, яр буеннан бер уч зәңгәр балчык алды, ул, көмеш нурлар чәчеп, бөтен тирә-юньдә таралып ята иде.

— Бу балчык өстендә кыш көне дә кар тормый, — диде Таһирҗан бабасы, бер капчыкка зәңгәр балчык тутырып. — Үзе салкын кебек тоелса да, ниндидер эчке җылылыгы бар аның, хәтта карны да эретә ул. Аны белеп, дөрес файдаланырга гына кирәк. Теге вакытта мин сине шуның белән генә аякка бастырдым бит, бөтен тәнеңне, җәрәхәтләреңне шуның белән сыладым. Чиләк-чиләк, арба-арба ташыдык без аны ул вакытта, мунчада шуңа ләгәнгә кереп ята идең...

Гөлҗиһан боларның барысын да хәтерли. Ул вакытта аңа бары тик шушы чишмә суын гына өшкереп эчерделәр, шушы зәңгәр балчык белән генә төреп тоттылар. Әйтерсең лә ул чагында болар аның тәнендәге бөтен зәхмәтен суырып алдылар. Башкалар тормаска дип авып калганда да, Гөлҗиһан аягына басты бит, әмма Чиләбедә авыруы тагы үзен исенә төшерде.

Гөлҗиһан зәңгәр балчыкны учларына кысты, битләренә тидерде. Балчык, тере җан иясе кебек, хәрәкәтләнеп, кыймылдап куйды, рәвешен үзгәртте, ул бер җылынды, бер суынды. Гөлҗиһан аны иснәп карады — зәңгәр балчыктан су исе, җил, күк исе килә иде. Тормышның үз исе.

«Гаҗәп, — дип уйлады Гөлҗиһан. — Училищеда болар турында укытмыйлар да, сөйләмиләр дә бит. Ә аяк астында күпме могҗиза аунап ята. Нигә моны галимнәр өйрәнми икән? Халык медицинасы дигәннәре шушы буладыр инде ул. Тик, Таһирҗан бабасы әйткәнчә, бу балчыкны файдалануның да үз тәртибе бар икән шул. Ул теләсә кемгә файда бирмәскә мөмкин икән. Бу шифалы су да, Аллакүлнең зәңгәр балчыгы да иманы нык кешеләргә генә ярдәм итә, ахры...»

Еллар үткәч, Гөлҗиһан бу шифалы балчыкның фәндә глауконит дип аталуын, аның бары тик биредә генә табылуын белер. Чернобыль авариясеннән соң бу балчык белән радиациягә дучар булган кешеләрне дәвалый башларлар. Зәңгәр балчыкның кеше организмыннан радионуклидларны чыгаруы билгеле булыр. Чирен биргән кебек, Аллаһ аның дәвасын да бирер.

Бабасының Гөлҗиһанга әйтер сүзе бар иде...

Ул аны күләгәрәк урынга, тау куышына таба алып китте. Әмма нигәдер бу хакта һаман сүз башларга ашыкмады, Гөлҗиһанның үзенең болар турында кузгатуын көтте. Картның аңа Фәргать турында хәбәре бар иде. Һәм ул хәбәр авыр, кайгылы хәбәр иде.

— Менә шулай яшәгән инде безнең халык, кызым, — диде ул, кытыршы ташны куллары белән сыйпап. — Динне дә белгән, табигатьне дә файдаланган, йөзгә дә җиткән. Ә хәзер иллегә дә җитмиләр. Син Исмәгыйль бабаңны хәтерләмисеңдер инде, безнең әти ул, шул әйтә торган иде: «Заман ахырында каты чирләр, кисәк үлемнәр күп булыр», — дия иде. Менә шул көннәр җитте, ахры, кызым. Һәм безнең нинди куәтле Алып Ханнар нәселенә дә үтеп керде бу зәхмәт.

Карт һаман кирәкле сүзен әйтә алмый интегә иде. Моны әйткәч, Гөлҗиһанның бөтен тормышы асты өскә киләсен, үзгәрәсен ул белә иде. Әмма мондый хәбәрне әйтмичә калырга да ярамый. Бәхетенә, бу хакта Гөлҗиһан үзе сүз башлады.

— Бабай, мин укып бетергәч, кая китим икән? — диде ул, үз проблемаларын исенә төшереп. — Киләсе язга безнең чыгарылыш бит инде. Авыру булгач, миңа сайлап алу мөмкинлеге биреләчәк, ягъни үзем теләгән җиргә китә алам. Бу кан белән Чиләбе өлкәсендә калмаска кушучылар да бар. Сезне ташлап, еракка китәсем дә килми. Фәргать белән дә һаман бер-бер ачыклык юк, суга төшкәндәй юкка чыкты. Биргән вәгъдәсендә тормады.

— Фәргатьнең хәле авыр, кызым, — диде Таһирҗан карт, бу хакта сүз кузгалуга. — Ул Иртәш больницасында ята икән.

Гөлҗиһан урыныннан сикереп торды, авып китмәс өчен, кыя ташына тотынды.

— Ә син кайдан белдең, бабай? — диде ул, хәле бетеп.

— Иртәштә күреп кайтканнар, — диде бабасы, бик тирән кереп торасы килмичә. — Хәле бик авыр, ди, баланың.

— Нәрсә булган соң аңа, Таһирҗан бабай, нигә әйтеп бетермисең, нәрсә булган Фәргатькә?! — дип өзгәләнеп кычкырып җибәрде Гөлҗиһан, тау куышын яңгыратып.

Аның тавышы, мәгарә эчләрен айкап чыгып, сулкылдап, кире үзенә кайтып егылды. Тирә-юньдә шактый вакыт «Фәргатькә... Фәргатькә... Фәргатькә...» дигән кайтаваз яңгырап торды.

— Фәргать сукырайган, кызым, — диде Таһирҗан карт.

— Су-кы-рай-ган?

Гөлҗиһан бу сүзне телен чак әйләндереп әйтә алды, аның күз аллары кинәт караңгыланып китте, тирә-ягы тау куышындагы кебек кап-караңгы булып калды. Күл буендагы

таш сыннар аның тирәсендә әйләнә башладылар һәм Гөлҗиһан белән бергә, гөрселдәп яр буена аудылар. Аңына килгәндә, ул Биташның аяк очында ята иде, бабасы аның кардай агарган битенә учлап салкын су сибә. Гөлҗиһан әле сөйләшә дә, эндәшә дә алмый, ярым мәет хәлендә күл буенда ята. Таһирҗан бабасы дога кыла да су сибә, дога кыла да су сибә. Ниһаять, Гөлҗиһан телен тибрәтер хәлгә җитте һәм аның беренче сүзе тагы «Фәргать» иде.

— Фәргать... Фәргать кайчан сукырайган? — дип сорады ул, янып кипшергән ираннәрен чак кыймылдатып.

— Армиядән кайтасы җәйне шулай булган, кызым, — диде Таһирҗан карт, аның аяк очына килеп утырып. — Ирташтә көчле давыл булган, ә боларны агулы күлдә эшләткәннәр. Солдатлар бит, кем алардан сорап торсын. Менә шунда сукырайган инде ул.

— Алайса, шуңа хәбәр бирмәгән инде ул, — диде Гөлҗиһан, әкрен генә торып утырып. — Бу хәлдә кеше күзенә күренәсе килмәгән.

— Анда кеше кайгысы булдымы икән, кызым? Күз хәтле күзне тишеп агызгач, башка җирләрен нишләтте икән ул агу? Анысын үзе генә беләдер инде.

Бабасының бу сүзләреннән Гөлҗиһанның йөрәге өшеп, туңып китте, бер мизгелгә тибеше дә тукталып торды кебек. Тагы егылмас өчен, Гөлҗиһан кесәсеннән тизрәк даруларын алды, аларны учлап эчеп җибәрде, артыннан Биташ суын йотып куйды. Бабасы аңа гаҗәпләнеп карап тора иде.

— Үзем дә хәзер шулар белән генә яшим, бабай, — диде дә Гөлҗиһан, аның күкрәгенә капланып, сулкылдап елап җибәрде.

Үзенең егерме яшеннән шушындый хәлдә булуыннан да, Фәргатьнең сукыраю хәбәреннән дә, әтисенең операция көтеп ятуыннан да үзәге өзелеп, ул чарасызланып елый башлады. Таһирҗан карт аны туктатмады, кайгысын эченә җыйганчы, күз яше белән чыгарып бетерүен яхшырак дип тапты.

Елап арыгач, Гөлҗиһан бит-күзләрен юарга күл өстенә иелде. Су төбеннән аңа, томырылып, Фәргать карап тора иде. Юк, ул сукыр түгел, аның коңгырт күзләрендә әйтеп бетергесез сагыш, сагыну күрде Гөлҗиһан. Үзен өзелеп, тилмереп көтү, чиксез ярату күрде. Аңа Гөлҗиһан кирәк, бик кирәк иде, әмма ул аңа йөк булырга да теләми иде...

Аллакүл суында Гөлҗиһан үзенең бөтен сорауларына да җавап тапкан кебек булды. Юк, ул үзенең яшәү мәгънәсен тапты — ул Фәргатькә кирәк иде. Бөтен кешегә караганда да, ул бүген Фәргать өчен бик кирәк иде. Һәм гомерен Гөлҗиһан аңа багышларга тиеш иде.

— Мин аны эзләп табарга тиеш, бабай, — диде ул, инде тыныч, ныклы тавыш белән. — Ул минем ярдәмгә мохтаҗ. Һәм мин аны бу хәлдә ялгыз калдыра алмыйм.

— Син аның ярәшелгән кызы, балам, — диде Таһирҗан карт, аның тынычланганына куанып. — Дөньяда әллә нәрсәләр була, үлеп терелгән кешеләр бар. Синеке кебек саф мәхәббәт күп нәрсәләр эшли ала. Иң мөһиме — кешенең күңел күзе сукыр булмасын, барына шөкрана итә белсен. Аллаһ авыруны ничек бирсә, шулай алырга да мөмкин, кызым. Болар барысы да безгә сынау инде, сынау.

Таһирҗан карт, аркасын кыя ташына терәп утырды да, күл өстенә карап, әкрен генә мөнәҗәт әйтә башлады. Бу мизгелләрдә ул әллә үз-үзе белән сөйләшә, әллә Гөлҗиһанга нидер аңлатырга тели, әллә күл суларына нидер әйтә иде. Бик борынгыдан килгән бу моң Гөлҗиһанның иң ерак кан күзәнәкләренә хәтле үтеп керде, аны уятырга, яшәртергә теләде, көчле, иманлы булырга өндәде. Бу — кечкенәдән Гөлҗиһан ишетеп үскән Караболак мөнәҗәте, Алып Адәм турында көйле җыру иде. Гөлҗиһанга иң авыр вакытларда, үлем белән тартышып ятканда, Таһирҗан бабасы аның баш очында гел менә шушы мөнәҗәтне әйтә иде. Бу — Караболак ирләренең Коръән ашларында күмәкләп әйтә торган мөнәҗәтләре, аны тыңлаганда Гөлҗиһанның тәннәре чымыр-чымыр килә, күзләре яшьләнә иде. Йөзгә җиткән ак сакаллы картларның, бергәләп, моңлы ирләр тавышы белән шулай мөнәҗәт әйткәннәрен Гөлҗиһанның башка бер җирдә дә очратканы булмады. Бу мөнәҗәт Караболак татарларының меңьеллык яшәү тәртибе, әхлак кагыйдәләре иде.

Бу дөньяда иң хөрмәтле — Адәм, дигән,
Бу дөньяны зиннәтләде Адәм, дигән.
Үз хөрмәтен үзе белсә — Адәм, дигән,
Үз хөрмәтен белалмаса — хайван, дигән.

Иң әүвәле кирәк нәрсә — Иман, дигән,
Китап-Коръән сүзләренә инан, дигән.
Китап-Коръән сүзләренә инанмасаң,
Ул кешене шайтан, дигән, дошман, дигән.

Икенче иң кирәк нәрсә — Намус, дигән,
Намусыңны югалтмаска тырыш, дигән.
Байлык өчен динен саткан адәм заты
Ике дөньясын да бергә сатар, дигән.

Өченче иң кыйммәт нәрсә — Гакыл, дигән,
Гакылсызның тәүфыйк ягы такыр, дигән.
Гакылсызда оят та юк, әдәп тә юк,
Кеше исемен күтәрүе гаҗәп, дигән.

Дүртенчесе иң кыйммәтле — Әдәп, дигән,
Әдәп кеше мәхәббәткә сәбәп, дигән.
Әдәпсездә бәхет тә юк, тәүфыйк та юк,
Кеше исемен күтәрүе гаҗәп, дигән.

Бишенче иң кирәк нәрсә — Инсаф, дигән,
Инсафлының күңеле дә бик саф, дигән.
Әдәп-Инсаф динебезнең яртысыдыр,
Рәсүлуллаһ шулай диеп хәбәр биргән.

Алтынчысы иң кыйммәтле — Күңел, дигән.
Күңле бозык кеше — кеше түгел, дигән.
Бозыкларга җир өстеннән асты яхшы,
Яшәмә гел, үлеп җиргә күмел, дигән.

Җиденчесе иң кыйммәтле — Сабыр, дигән,
Сабыр кеше зур бәхетләр табар, дигән.
Бер дә юктан ачуланып, дөнья бозу
Бер кайгыдан икенчегә салыр, дигән.

Янә тагы кирәк нәрсә — Шөкер, дигән,
Нигъмәткә шөкер сүзе табар, дигән.
Яткан җирдә, Ходай, кичер, дию хурлык,
Сәбәп эзләп, төз юл белән йөгер, дигән.
Рәсүлуллаһ юлы белән йөгер, дигән.

Адәмгә ниләр кирәк? Моны Караболакта бик яхшы беләләр иде. Нинди генә шартларда да, хәтта муеннан агу эчендә яшәсәң дә, иң беренче чиратта, Кеше булып калырга кирәк иде. Караболакта исә кеше булып калуны әдәп-әхлакта, яхшы холыкта, миһербанлыкта күрәләр иде. Таһирҗан бабасы Гөлҗиһанга боларны тагы бер тапкыр исенә төшерде, нинди генә кайгылар килсә дә, сабыр итә белергә, Кеше булып калырга өндәде.

Алар әкрен генә кайтырга кузгалдылар.

Күл буендагы җимерек таш сыннар, тирән уйга батып, аларны озатып калдылар. Үз гомерләрендә күпне күрделәр, күпне кичерделәр инде алар, таш гасырларны, кешелекнең беренче чорын искә төшереп, әле менә һаман басып торалар. Бу тау куышларында беренче кешеләрнең аяк эзләре, учак урыннары саклана, бөек татар тарихы саклана. Әле генә Аллакүл буенда булып киткән татарларда Алып Ханнар нәселе саклана. Һәм дәвам итәргә тиеш. Атомнарны җиңеп, җирдә бу нәсел, бу милләт калырга тиеш, чөнки алар адәмгә ниләр кирәген инде беләләр иде.

Авыл башында аларга каршы йөгергән бер хатын-кызны күреп, Гөлҗиһан курка калды. Әллә соң әтисенә берәр нәрсә булганмы, Ходаем? Чәчен-башын туздырып үзләренә каршы йөгергән бу хатын-кызны башта ул бөтенләй танымады, чөнки алар авылында мондый кеше юк иде. Әмма якынрак

килгәч, аның йөзен күргәч, Гөлҗиһан имәнеп китте, бу — классташы Рәшидә иде. Аның киезләнгән чәчләре яулык астыннан бүлтәеп чыгып тора, йөзен газап җыерчыклары баскан, өстендәге күлмәге искереп, таушалып беткән. Ул йөгереп килгән уңайга Гөлҗиһан алдында туктап калды, оялып, бер читкә карап тора башлады. Гөлҗиһан үзе аның кулларыннан тотып алды, яратып һәм кызганып күкрәгенә кысты. Рәшидә, язмыш тарафыннан кыерсытылган бала кебек, борынын аның җилкәсенә төртте. Гөлҗиһан бабасына кайта торырга кушты һәм үзе Рәшидә белән калды. Ул капчыгындагы бер шешә Биташ суы белән Рәшидәнең тузанлы биткулларын юды, башындагы яулыгын селкеп япты.

— Син, Рәшидә, әйдә, минем белән безгә кайт, мин сиңа матур күлмәкләр бирермен, — диде ул, нәрсә әйтергә белмичә.

— Ә миңа төймә кирәк, — диде Рәшидә, аңа ихлас күзләре белән карап.

— Төймә? Нинди төймә, мәрҗәнме?

— Юк, — дип көлә башлады Рәшидә, бала чагындагы кебек пырхылдап. — Кесәңдәге төймәләр турында әйтәм мин. Син брач бит хәзер. Мине терелтергә кайттың авылга, мин беләм.

Гөлҗиһан ашыгып кесәләренә тыгылды һәм аннан бер уч дару тартып чыгарды. Әйе, бу аның йөрәктән, каннан, басымнан, бавырдан эчә торган дарулары. Ә Рәшидә каян белде икән бу турыда? Хәер, эш андамыни, әгәр бу дарулар Рәшидәгә дә ярдәм итә икән, һичшиксез, барысын да бирергә кирәк. Аларның барысында да бер авыру бит инде. Халык телендә әйткәнчә, «елга авыруы».

— Мин сиңа бирәм аларны, Рәшидә, — диде ул, даруларны аның учына салып. — Тик син аларны берәмләп кенә эч, яме? Көнгә өчне генә эч. Артык ярамый.

— Беләм инде, беләм, — диде Рәшидә, даруларны тизрәк кесәсенә яшереп. — Өчкә хәтле генә саный беләм инде мин, биш класс укыдым бит. Мин бу төймәләрне башкаларга да бирәм әле, яме? Тик көненә өчне генә! Артыгы ярамый! Брач шулай диде.

Шулай диде дә Рәшидә, авыл буйлап торып йөгерде. Караболакта бүген аннан да бәхетле кеше юк иде. Ул өй саен кереп, авыл халкына берәмләп Гөлҗиһанның даруларын таратып йөрде. «Брач апа бирде, көненә өчәрне генә эчәргә кушты» дип, һәрберсен өйрәтеп чыгып китте. Ул Гөлҗиһаннарга күлмәккә килергә дә оныткан иде, Гөлҗиһан үзе олы бер төенчек өс-баш җыеп, энеләре артыннан Рәшидәләргә җибәрде. Күңеленнән алга таба да авылга булдыра алганча дарулар алып кайтырга, кулыннан килгәнчә ярдәм итәргә ниятләп куйды.

Классташы Рәшидәне ташламаска да күңеленнән карар итте Гөлҗиһан. Рәшидә белән очрашу аның бөтен күңелен айкап ташлады, ул тагы үз хәлен аныкы белән чагыштырып карады. Әтисен, сукыраеп яткан Фәргатьне күз алдына китерде. Аларның барысына да Гөлҗиһан кирәк иде. Алар аның ярдәменә мохтаҗ, аннан ярдәм көтеп яталар. Гөлҗиһанның хәзер үз хәлен уйлап, мәлҗерәеп, авырып ятарга хакы юк иде, вакыты да юк. Иртәгә иртүк ул әтисе белән Чиләбе больницасына чыгып китәргә тиеш иде.

## Унсигезенче бүлек

Гөлҗиһанның әтисен Чиләбенең халык телендә ФИБ дип аталган фәнни-тикшеренү институты больницасына салдылар.

Иртәш буйларыннан, Коншак тирәсеннән каты авыру белән килүчеләрне барысын да шушында яткыралар иде. Халык телендә бу больница турында берсеннән-берсе шомлы хәбәрләр йөри: имеш, монда авырулар өстендә нииндидер сынаулар үткәрәләр икән, моңа кадәр кеше эчеп карамаган өр-яңа даруларны шуларда сынап карыйлар, ди. Кеше шуны эчеп үлсә үлә, калса кала икән. Имеш, аларны тәҗрибә этләре белән янәшә бүлмәләрдә тоталар, ди, сынау вакытында эт үлмәсә, шуны кеше өстендә дә үткәреп карыйлар икән, дип сөйли халык. Ә үзе барыбер шунда бара, чөнки Караболакларны да, Мөслимнән килгәннәрне дә башка җиргә алмыйлар, туп-туры ФИБка җибәрәләр. Авыл халкының үзенә әйтмәсәләр дә, аларның нурланыштан һәм рактан чирләгәнен белә Чиләбе табиблары, һәм шуңа күрә аларны ФИБта гына кабул итәләр. Бирежән бик сирәкләр генә исән чыга, алар да бераз вакыт үтүгә, тагы монда әйләнеп кайталар. Мәетләрнең исә авылга күмәргә коры гәүдәләрен генә кайтаралар, аларның бөтен эчке әгъзалары тәҗрибә өчен больницада алып калына. Бавыр-бөерләргә күпме радиоактив матдәләр, плутоний, стронций утырган, кеше шулардан күпме түзгән — барысын да белергә кирәк совет табибларына. Мәетләрнең хәтта сөякләрен, тешләренә хәтле шулай аерып алып өйрәнәләр, шуңа күрә татар авылларына күмәргә җип-җиңел буш гәүдәләр генә кайта.

Коншактан килгән «ашыгыч ярдәм» машинасы Гөлҗиһанның әтисен туп-туры шушы ФИБка китереп салды. Бәхетенә, Гөлҗиһан биредә практика үткән иде, авыруларга укол ясарга, җәрәхәтләрне бәйләргә дә ул шушында өйрәнде. Каннан курыкмагач, җитезлеген искә алыпмы, аны еш кына операция ясаганда чакыралар иде. Гөлҗиһан беркайчан да ике әйттерми, бер карауда нәрсә кирәген аңлап ала, бөтен эшне

җиренә җиткереп эшли. Шуңа күрә аны ФИБта бик яраттылар, укып бетергәч, үзләренә эшкә дә чакырдылар. Гөлҗиһан авырулар арасында бик күп татарларны, шул исәптән үз авылдашларын да еш күрә иде. Аларның барысында да диярлек Гөлҗиһандагы кебек авыру иде.

Әтисен ФИБка урнаштырырга да Гөлҗиһан үзе йөгереп йөрде, кирәкле табибларын, палатасын тапты, бар мәшәкатьләрне дә бик тиз һәм ыгы-зыгысыз ерып чыкты. Бәхетенә, аның таныш табиб апасы Галия дә биредә эшли иде, Гөлҗиһанның әтисенең бөтен анализ, кәгазь белән бәйле эшләрен ул үз өстенә алды. Һәм гомерендә беренче тапкыр Гөлҗиһан үзенең шушы һөнәрне сайлавына сөенеп бетә алмады, язмыш аны менә шушы көннәр, шушы сынаулар өчен әзерләгәнен аңлады. Иң мөһиме — Гөлҗиһан башкаларга кирәк, ул кешеләргә ярдәм итә ала иде. Моның дөньяда бик зур бәхет икәнлеген Гөлҗиһан менә хәзер аңлый башлады.

Әмма көн саен кеше кайгысын күреп торуның нинди газап икәнлеген ул әле аңлап бетерми иде. Язмыш аңа монысын да бик тиз күрсәтте — табиблар, җыелып киңәшкәннән соң, әтисенең аякларын кисәргә кирәк дигән карарга килделәр. Анализлар күрсәтүе буенча, аның аякларында күзәнәкләр инде үлеп баралар, моны вакытында кисеп ташлап туктатмасаң, черү бөтен гәүдәгә таралырга мөмкин. Бер генә нәрсә бәхәс уятты — тезеннән кисәргәме аякларын, бот төбеннәнме? Тездән киссәң, ул әле тормышка яраклы кеше булырга мөмкин, бот төбеннән киссәң, тере гарип булып, кеше кулына калачак. Әлбәттә, аны карарлар, Гөлҗиһан үзе дә, әнисе дә, әби-бабасы да аны гомер буе карарга әзерләр. Әмма кеше кулына карап ятарга әтисе үзе риза булмаячак. Әгәр авыру бик таралмаган икән, тездән кисү белән генә чикләнергә кирәк иде.

Бу авыр эштә арадашчы булырга Гөлҗиһанга туры килде. Ул табиблар белән дә, әтисе белән дә үзе сөйләште. Бу үткен татар кызының еламыйча, каушамыйча шундый җитди, куркыныч нәрсәләр турында ачыктан-ачык сөйләшә алуы урыс табибларын да гаҗәпләндерде. Ә үз хәлен Гөлҗиһан үзе генә белә иде, бу көннәрдә аңа йөрәген йомарлап учына кысарга туры килде, хисләрен, күз яшьләрен тышка чыгарырга аның хакы юк иде. Әтисе, аяксыз калып, аның күзенә карап ята иде. Эшне сузган очракта, аның үлеп китүе дә бар.

Гөлҗиһан әтисенә боларның барысын да әйтмәде, әмма операция кирәклеген әйбәтләп кенә аңлатты. Әтисе бу авыр хәбәрне сабыр гына кабул итте, башка чара юклыгын ул аңлый иде. Ул кызына бөтен күңеле белән ышанды, язмышын хәл итүне дә аңа тапшырды. «Син ничек дип әйтсәң, шулай булыр, кызым, син шушыңа укыган бит, беләсең», — диде ул,

кыска гына итеп. Шулай итеп, Нәбиулланың ике аягын да тездән кисү хәл ителгән иде.

Табиблар тагы бер тапкыр аның анализларын алдылар, тикшерделәр һәм хәзергә аякларны тездән кисү дә җитеп торыр дигән нәтиҗәгә килделәр. Башка очрак булса, аны утын тумраны кебек тураклап ташларлар иде, әмма монда кызы Гөлҗиһан, таныш табиблар булгач, тәҗрибәләр белән мавыкмаска булдылар. Караболак, Мөслимнән аяк-кул кистереп ятучылар бер Нәбиулла гына түгел, мондый операцияләр Чиләбе табиблары өчен гадәти бернәрсәгә әйләнгән иде.

Элеккеге тәҗрибәсен искә алып, операция вакытында Гөлҗиһанга да катнашырга рөхсәт иттеләр. Табиблар якын туганнарның мондый эштә катнашуларын өнәп бетермәсәләр дә, Гөлҗиһан башка мәсьәлә иде. Беренчедән, ул монда барысының да яратканы, аларча әйтсәк, «любимчигы», икенчедән, Гөлҗиһан үзе бик ялынып сорады операциядә катнашырга. Табиблар аңа: «Үз күзләрең белән күрү күңелеңә авыр булыр, кереп торма», — дисәләр дә, Гөлҗиһанның авыр вакытында әтисе янында буласы килде. Бу мизгелләрдә ул аның сакчы фәрештәсенә әйләнгән иде.

Янында кызы булгач, Нәбиулла да тыныч иде. Ул, Гөлҗиһанның күзләренә карап, наркоз йокысына китте. Гөлҗиһан исә операция өстәле янында шәфкать туташына әйләнде. Язмыш аңа шундый авыр сынау әзерләгән иде — әтисенең аякларын Гөлҗиһан үзе кисеште. Ул табибларга кирәкле җиһазларын биреп торды, бинт, мамык, башка кирәк-яракларын әзер тотты. Битлек астыннан аның зур яшел күзләре генә түгелергә әзер булып, мөлдерәп карап тора иде. Әмма гаҗәп авыр бу эшне башкарып чыкканда, аның ник бер керфеге селкенсен, ник бер тапкыр куллары калтырасын. Шушы операция вакытында нәкъ маңгай турыннан бер тотам чәче агарганын соңыннан гына күрер Гөлҗиһан. Бу егерме яшьлек кыз баланың әтисе кайгысыннан агарган тәүге чәчләре булыр. Аннан соң Фәргать өчен агарыр аның чәчләре, балалары өчен чал төскә керер... Ә хәзергә Гөлҗиһан әтисенең аякларын кисүдә катнаша.

Чөнки шулай эшләмәсәң, ул үләргә мөмкин.

Тормышның кырыслыгы, рәхимсезлеге аны да катыландыра, кырысландыра. Һәм шушы рәхимсез тормышка каршы ул керпе кебек йомарлана, энәләрен чыгара. Әтисе янында елап утырып мәсьәләне хәл итеп булмаганын ул яхшы аңлый. Таһирҗан бабасы әйтмешли, «бу хәлдән чыгуның сәбәбен эзләп, төз юл буйлап йөгерә...» Әле аңа бөтен гомере буена шулай йөгерергә, тормышның һәр бәхетле мизгеле өчен җан атып көрәшергә, һәр кайгы-хәсрәт өчен дөрли-дөрли

янарга туры киләчәк. Тәкъдирендә язылган гомере беткәнче, шулай янып, көрәшеп яшәргә туры киләчәк.

Әтисенең операциясе уңышлы чыкты. Операциядән соң да Гөлҗиһан аның яныннан китмәде, уколын да үзе ясады, яраларын да үзе юып бәйләде, ашатуын да үзе ашатты. Әллә кызының янында булуына, әллә авылдан бертуктамый якыннары килеп торганга, Нәбиулла күзгә күренеп тернәкләнә башлады. Ул үзе дә нык, көчле ихтыярлы кеше иде, гел терелү уе белән яшәде. Таһирҗан карт исә Аллакүл сулары, өшкергән зәңгәр балчык, төрле үлән-тамырларны Караболактан ташып кына торды, үзе килә алмаса, кеше артыннан биреп җибәрде. Гөлҗиһанның җәйге ялда булуы да ярап торды, уку вакыты булса, ул әтисе янында болай көне-төне була алмас иде...

Гөлҗиһан әтисендәге сабырлыкка, ихтыяр көченә гаҗәпләнеп бетә алмады.

Тездән ике аяксыз калса да, ник бер ыңгырашсын, зарлансын, өметсезлеккә бирелсен! Әле: «Чуен аяк яхшырак булырмы, агачы да ярап торырмы хәзергә», — дип, планнар корып ята. Җәрәхәтләре бераз төзәлүгә, Таһирҗан бабасы кайдандыр белешеп тә кайтты, тездән тимер аяклар ясатырга килештеләр. Гөлҗиһан шуңа да игътибар итте — бу больницада алар авылыннан шактый кеше ята иде һәм алар аның әтисе яныннан чыгып тормадылар. Әйтерсең лә бөтен Караболак монда күчкән — рәхәтләнеп татарча сөйләшәләр, авыл хәлләрен белешәләр, үз кайгыларын онытып торып, шушы шартларда да кеше булып яшәргә тырышалар. Биредә бөтен Коншак районыннан татарлар ята, әмма иң күбе — Мөслимнән, Татар Караболагыннан, Үзбәгәрәктән, Мусакайдан, Сарыкүлмәктән булып чыкты. Алар, ахырзаман әрвахлары кебек, торган урыннарыннан кубарылып, шушы урынга җыелганнар. Кемнедер монда исән калырмын дигән өмет китергән, кемнедер — көчле авыру, кемнедер үлем куркынычы бирегә куып керткән. Бөтен Иртәш, Караболак, Сәнәр, Теча буйлары купкан. Табибларның үзара чыш-пыш сөйләшүләреннән шуны да аңлады Гөлҗиһан — болар барысы да Иртәш белән бәйле авырулар икән. Атом чирләре. Әмма бу хакта кычкырып әйтергә ярамый иде.

Ул арада, җәйге каникуллар бетеп, училищеда укулар башланды. Гөлҗиһанның әтисен дә килгән машинасы белән яңадан Караболакка алып кайтып киттеләр. Инде хәзер Гөлҗиһан әтисе өчен тыныч иде — ул, тимер аяк белән булса да, яңадан җиргә басты, яши, эшли башлады. Аның янында фәрештә кебек Хәбирәсе, әти-әнисе, әүлиядай Таһирҗан карт, балалары, Караболак халкы бар иде. Алар аны бергәләп яңадан аякка бастырдылар, үз җилкәләрен куйдылар, инде аварга

ирек бирмәячәкләр. Ул хәзер Гөлҗиһанның ярдәменә мохтаҗ түгел, аның ярдәменә бүген иң мохтаҗ кеше — Фәргать иде. Әтисе кайгысы белән ул аның турында бераз уйламыйча торса да, Фәргать хәсрәте Гөлҗиһанның башыннан беркайчан да чыкмады. Фәргать исенә төшү белән, аның җаны сулкылдый башлый иде, ул үзен нәрсәдәдер гаепле кебек сизә. Гөлҗиһан белә — ул Фәргатькә ярдәм итәргә тиеш, әмма ничек итеп? Фәргать үзе аннан ярдәм сорамый, әмма Гөлҗиһан шушындый хәлдә калса, ул аңа ярдәмгә килер иде. Дөнья читенә барыр иде ул Гөлҗиһанны эзләп, аңа ярдәм итәр өчен. Сукырайса, кулларына күтәреп йөртер иде, кашыклап ашатыр иде, әмма беркайчан да ташламас иде. Юк, ташламас иде.

Ә Гөлҗиһан?

Фәргатьнең шушы хәлдә калганын белә торып, ул нигә берни эшләми соң? Нигә ул Фәргатьнең чакырганын көтеп ята, бәлки, ул чакырырлык хәлдә түгелдер? Бәлки, Гөлҗиһанга үзенә аның янына барырга, эзләп табарга, аңа ярдәмгә килергә кирәктер? Гөлҗиһан менә шушы гаять җитди сорауларга җавап табарга һәм бер карарга килергә тиеш иде. Һәм Гөлҗиһан язмышында язылган ул карарга килде — училищены тәмамлаганда, ул Иртәшкә китәргә юллама сорады.

Әйе, Гөлҗиһан эшкә Иртәшкә, атом каласына китәргә булган иде.

Аның бу теләге күпләрне гаҗәпкә калдырды. Гел бишкә генә укыган, группада иң тере, иң булган Гөлҗиһанны Чиләбенең теләсә кайсы больницасында бишкуллап эшкә алалар иде. Авыруы буенча, аның Чиләбе өлкәсеннән читкә китәргә дә хакы бар, чөнки табиблар мондый начар кан белән башка урында яшәп карарга тәкъдим итәләр. Ә ул әнә шул авыруларның үзәге булган Иртәшкә юллама сорый! Балалар кебек ихлас, хан кызларыдай горур һәм гүзәл бу татар кызы белән аның таныш татар табибы үзе сөйләшеп карарга булды. Ул аның мондый карарга килгәнен аңламады да, кабул да итмәде.

— Эшкә Иртәшкә сорагансың икән, сеңелем, — диде ул, Гөлҗиһанны каршына утыртып. — Синең сәламәтлегең өчен бик үк кулай урын түгел бит ул.

— Беләм, Галия апа, — диде Гөлҗиһан. — Әмма мин анда барырга тиеш. Бу инде минем өчен хәл ителгән нәрсә.

Табиб хатын Гөлҗиһанның шулхәтле катгыйлыгына хәтта аптырап та куйды. Нәрсә тарта аны бу үлем шәһәренә? Ул бит анда үзен нинди хәлләр көткәнен белми, яшьлеге белән шулай башсызлана. Гөлҗиһанны, милләттәше буларак, ярата һәм кызгана иде ул, шуңа күрә аны, һич кенә дә күрә торып, белә торып, атом базына җибәрәсе килмәде. Бу бала-

га бар дөреслекне дә әйтеп бетереп булмый, бу тыелган нәрсә. Яшьлеге белән ул аны аңларлык та түгел әле, аңласа, анда ыргылмас иде. Мондый кан, мондый авырулар белән Иртәштән генә түгел, Чиләбенең үзеннән качарга кирәк. Әгәр яшисең килсә, әлбәттә.

— Мондый кан белән сиңа анда барырга ярамый, сеңелем, — диде ул, җитди итеп. — Ул шартларда синдә бик тиз ак канга әйләнү башланырга мөмкин, ягъни лейкемия. Син хәзер дипломлы медик, моның нәрсә икәнен яхшы беләсең. Сиңа бу уеңнан кире кайтырга кирәк, сеңелем.

Әйе, моның нәрсә икәнен Гөлҗиһан яхшы белә. Нәрсә белән бетәсен дә чамалый. Әмма аның иң кадерле кешесе, яшьлек мәхәббәте шушындый хәлдә булганда, Гөлҗиһан үз авыруын уйлап, үлемен көтеп утыра алмый. Таһирҗан бабай әйткәнчә, «Әҗәл чакырып килмәс, килсә, кусаң да китмәс...» Язмышында нәрсә язылган булса, шул булыр, әмма Гөлҗиһан Фәргатьне эзләп табарга тиеш. Ә ул аны бары тик Иртәштә генә таба ала.

— Мин хәл иттем инде, апа, — диде ул, эчке бер үҗәтлек белән. — Анда да кешеләр яши, больницалар бар, минем ярдәмемә мохтаҗ авырулар бар. Хәзер медицина көчле, егылып үләргә ирек бирмәсләр әле. Мин анда эшләргә дип барам бит, үләргә түгел кый!

Гөлҗиһанның бу сүзләреннән табиб хатын елмаеп куйды. Шушы хәтле дә үзсүзле үткен мишәр булыр икән! Тәки үз сүзен әйтеп тик тора бит. Әллә ул яшьләрне аңламый башлады, әллә яшьләр аны аңламый. Ә бу бер дә шаяра торган нәрсә түгел бит, анда бу бала белми торган нәрсәләр дә бар.

— Ә син аның яшерен, ябык зона икәнен беләсеңме соң? — дип сорады ул, тавышын шактый әкренәйтә төшеп. — Анда бит болай гына кереп-чыгып йөреп булмый. Бер керсәң, тиз генә чыга алмассың. Аларын да уйлап бетердеңме?

— Беләм, Галия апа, — диде Гөлҗиһан. — Безнең авыллар күп эшли анда. Мин кайда барганымны яхшы беләм.

— Анда радиация барлыгын да беләсеңме?

Гөлҗиһан, җавап бирә алмыйча, төртелеп калды. Бу хакта да аз-маз ишетеп белә ул, училищеда да бераз укыдылар, больницада да бу хакта шыпырт кына сөйләшкәннәрен ишетте. Әмма аның бу өлкәдә бар белгәне шуннан артмады, ул әле радиация белән үз авыруларын бергә бәйли алырлык дәрәҗәдә түгел иде. Әле илдә бу турыда ялгышып та сүз кузгатучы юк иде. Радиациянең нәрсә икәнен белү өчен әле тагы егерме ел вакыт үтүе, Чернобыль атом электр станциясе шартлавы, ярты дөньяның шул радиациядән кырылып бетүе кирәк иде...

— Нәрсә булса да, барам, апа, — диде Гөлҗиһан, үз сүзендә нык торып.

— Авыру әтиеңне, авылдашларыңны да калдырып барасыңмы, Гөлҗиһан?

Табиб хатын Гөлҗиһан өчен иң авыр сорауны бирде, аңа җавап та чын дөресе булырга тиеш иде.

— Әйе, апа, барыбер барам. Әти янында әни бар, туганнар бар, авылдашлар да ялгыз түгел. Ә Фәргать ялгыз, берүзе.

Шулай диде дә Гөлҗиһан, үксеп елап җибәрде. Әле генә чакматаш кебек үзенекен чатнатып утырган бу кызның кинәт балалар кебек үксеп елап җибәрүеннән табиб хатын куркып калды. Кем соң ул Фәргать, нәрсә булган аңа? Аннан аның зиһене ачылып, яктырып китте — әлбәттә, йөргән егете, мәхәббәте бар бу кызның Иртәштә, шулай булмаса, ут эченә керергә атлыгып тормас иде ул!

— Егетең шундамыни, сеңелем? — дип сорады ул, Гөлҗиһанның чәчләреннән сыйпап.

— Әйе, апа. Без аның белән ярәшелгән идек, инде дүрт ел элек туй буласы иде. Ә Фәргать кайтмады...

— Ул Иртәштә идемени?

— Әйе, ул анда армия хезмәтендә иде. Кайтасы көзне әниләренә телеграмма җибәргән, өстәмә хезмәткә калдым, дип. Ә миңа бернәрсә хәбәр итмәде. Мин быел гына аның анда сукырайганын белдем, Иртәштән безнең авыллар ишетеп кайтканнар.

Табиб хатын барысын да аңлады.

Сөнкүлдә эшләгәндә, ул андый хәлләрне күп күрде. Көчле радиациядән, нурланыштан сукырайган авыруларны Иртәштән аларга китерәләр иде. Бигрәк тә тоткыннарны, солдатларны, ягъни үз ирекләрендә булмаган кешеләрне. Һәм алар өстендә бөтен сынау-тәҗрибәләрне үткәрәләр иде, тереләй туныйлар иде аларны. Дөрес, ул үзе мондый эшләргә беркайчан да катнашмады, шуңа күрә Сөнкүлдә озак эшли дә алмады. Әмма анда күргәннәре бөтен гомеренә җитәрлек булды.

— Егетең. Иртәштәме, әллә Сөнкүлдәме икән?

— Белмим, — дип сузып кына җавап бирде Гөлҗиһан. — Аның Сөнкүле дә бармыни әле? Миңа Иртәштә диделәр. Шуңа күрә шунда барам мин.

— Алайса, бар, сеңелем, — диде табиб хатын, бер карарга килеп. — Сөйгәнең шундый хәлдә икән, бар. Гомер бер генә килә. Саф мәхәббәт тә шулай. Аңа хәзер синең ярдәмең бик кирәк. Коткар син аны, тизрәк коткар аннан. Яшьлегемдә булсам, мин дә нәкъ шулай эшләр идем.

Аның күзләренә яшь бәреп чыкты...

Атом утында көйгән яшьлеген искә төшердеме ул, сөйгән

ярсыз, гаиләсез, балаларсыз узган гомерен күз алдына китердеме, авыру картлыгын уйлап еладымы — белеп булмый иде...

Алар Гөлҗиһан белән кочаклашып аерылдылар. Үзендә атом тамгасы йөрткән өлкән яшьтәге татар хатынын ялгыз картлык, шундый ук авыруга дучар булган татар кызын билгесез киләчәк көтә иде...

## Унтугызынчы бүлек

Инде алтмышынчы елларның азагы якынлашса да, инде Сталин белән Берия күптән үлгән булсалар да, Сөнкүлдә алар урнаштырган тәртип, алар төзеп калдырган үлем индустриясе бөтен көченә эшләп ята иде. Иртәштә атом реакторлары күбрәк эшләгән саен, дөньяга радиация күбрәк таралган саен, Сөнкүлдәге тәҗрибә лабораторияләре дә ныграк кирәк була башлады.

Ябык шәһәргә Мәскәүдән профессорлар, яшерен белгечләр килеп җитте, немец галимнәре белән берлектә алар радиациянең кеше организмына тәэсирен өйрәнделәр, концлагерьлардагы кебек, тере кешеләр өстендә тәҗрибәләр үткәрделәр. Немецларның бу өлкәдә тәҗрибәләре зур иде, алар 1933 елдан башлап сугыш беткәнче гарипләр, тиленләр һәм әсирләр өстендә күп радиацион сынаулар үткәреп караганнар иде инде. Үзләре совет гаскәрләре кулына әсир булып төшкәч, аларны Сөнкүлгә китерделәр һәм инде совет кешеләре өстендә атом сынаулары үткәрергә мөмкинлек бирделәр. Совет белгечләре алардан өйрәнеп тордылар, шулай итеп, тере кешеләр өстендә атом сынавы уздыру буенча зур тәҗрибә тупладылар. Тиздән бу немец галимнәре үзләре дә нурланыштан һәм рактан Сөнкүл больницасында үлеп беттеләр, әмма алар өйрәтеп калдырган эш, кешеләр өстендә куркыныч тәҗрибәләр дәвам итте.

Галимнәр өчен радиациянең нәсел калдыруга тәэсирен өйрәнү бик мөһим иде, шуңа күрә алар авыруларны махсус нурланыш астында калдырып, нәсел өчен җавап бирә торган күзәнәкләрен юк иттеләр. Исән калганнарын Сөнкүл гарипләр йортына урнаштырып, махсус өйләндереп, алар өстеннән күзәтүләрен дәвам иттеләр — мондыйлардан бала туамы, туса, нинди туа, бу балаларда кайсы якка үзгәреш көчлерәк була? Сөнкүл больницасында күпләп яткан дивана һәм тиленләрнең алар баш миләрен өйрәнделәр, арка миләреннән сыеклык алып, аны үз акылында булганнарга җибәреп карадылар. Авыруларны нормадан йөзәр, меңәр тапкыр көчлерәк булган рентген нурлары астында тоттылар, моннан соң аларны ярып карап, организмдагы үзгәрешләрне өйрәнделәр. Этләр өстендә нинди тәҗрибә уздырылса, монда кеше-

ләр өстендә нәкъ шуларны эшләп карадылар. Барысы да фән өчен, совет халкының бәхетле киләчәге өчен дип эшләнде. Берәүләрнең бәхете өчен икенчеләр тереләй корбан булырга тиеш иделәр.

Татар егете Фәргать менә шушы үлем тегермәненә килеп эләккән иде.

Күзләре сукырайган мизгелдән Фәргать өчен тормыш тукталды...

Бөтен эчен утлы пычак белән даими айкап торган көчле авыру да аны уята, хәрәкәтләндерә алмады, әйтерсең лә Фәргатьнең җаны үлгән иде. Ул үзен бөтен яктан чорнап алган караңгылыкны җиңә алмады, киресенчә, кара упкын аны җиңә, әкрен генә йота башлады. Үзенең сукыраюын белгән мизгелдән Фәргатьтә тормышка карата битарафлык башланды, аңа хәзер бу салкын гәүдә белән нишләсәләр дә барыбер иде. Гәүдәне, арбага салып, әледән-әле операциягә алып чыгып китәләр, әле бер җирен, әле икенчесен кисеп туныйлар. Укол бирәләр дә туныйлар, укол ясыйлар да кисәләр. Нәрсәне кисәләр, нәрсәне туныйлар алар — сукыр Фәргать бернәрсә белми. Нәрсә киссәләр дә, аңа хәзер барыбер иде. Әмма иң кирәгенә — аның күзләренә операция ясамадылар, чөнки көчле радиация аның күз алмаларын көйдергән, нурын сүндергән иде инде.

Әзмәвердәй егет, кисеп ташлаган имән кебек, айлар буе больница караватында аунады.

Аннан табиблар ярдәме белән Миасска, әниләренә телеграмма бирдерде. Ул үзенең сукырайганын, больницада ятканын әйтмәде, Иртәштә өстәмә хезмәткә калам, дип ялганлады. Гөлҗиһанга исә бер хәбәр дә бирмәде, күрше кызы Гөлҗиһан, туй, мәхәббәт кара пәрдәнең теге ягында калган иде. Бу якка, бу тормышына ул егерме бер яшьлек сукыр булып, гарипләнеп, берьялгызы чыкты. Аның янында әнисе дә, туганнары да, сөйгән яры да юк инде. Мондый мескен кыяфәттә ул аларның берсенә дә күренәсе килмәде. Гөлҗиһанга бигрәк тә. Гөлҗиһан — яшь, матур кыз, ул бәхетле гаилә тормышы, итәк тулы балалар турында хыяллана иде. Ә Фәргать аңа боларның берсен дә бирә алмаячак. Аның балалары булмаячак. Димәк, ул хәзер Гөлҗиһан турында да, гаилә тормышы турында да онытырга тиеш. Онытырга тиеш...

Чираттагы операциядән соң Фәргатьне башка бинага күчерделәр. Әмма ул үзе моны белерлек хәлдә түгел иде, кайда алып барсалар да, нәрсә эшләсәләр дә, ул үзен якларлык хәлдә түгел иде. Башы-тәне бинтка чорналып, ул күпме гомер ятканын да хәтерләми, әмма ниндидер моңлы, үзәк өзгеч сагышлы тавышка аңына килде. Ул яткан бүлмәдә кемдер татарча җырлый иде:

Әйә, агач, яшең күпме,
Коелган яфрагың күпме?
Минем күк хәсрәтең күпме,
Дип сорадым агачлардан...

Башта Фәргать үзен каты авырудан саташам икән дип уйлады. Чөнки элегрәк тә аның шулай аңын җуйганда, төрле тавышлар ишеткәне бар иде. Ул әле әти-әнисенең, әбибабаларының тавышын ишетә, әле Гөлҗиһанның чыркылдап көлүләре гел колагында яңгырап тора иде. Бу юлы да ул шулай саташып берәрсенең тавышын ишетәм дип уйлады, чөнки мондый мөнәҗәтне әбисе гел әйтә иде. Әле Караболакта яшәгәндә үк, Фәргать кечкенә вакытта, әбисе аны кабык арбага салып, шушы көйгә тибрәтә иде. Аннан, теге вакытта авылдан куганда, әнисе Фәргатьне куенына кысып, юл буе шушы сүзләрне иңрәп барган иде. Миасска барып урнашкач та, моңлы чакларында әнисе дә, әбисе дә шушы мөнәҗәтне әйтәләр иде.

Үләр идем, үләр хәл юк,
Бу хәлләргә түзәр хәл юк.
Киңәш итәр кешем дә юк,
Сабырлык бир үзең Алла...

Фәргать бу көйне тетрәнеп тыңлады. Ул инде наркоздан айныган иде, үзенең саташмавын, бу татарча җырны чыннан да өнендә ишетүен аңлаган иде. Ул яткан бүлмәдә кемдер бар, ахры, тирә-якка хлор исе таралган, чиләк сабы чылтыраган, йөргән тавышлар ишетелә. Идән юучы татар хатыны эш арасында әкрен генә тавыш белән моңлануын да дәвам итә:

Чиксез димә гомереңне,
Якын дип бел үлемеңне.
Сәхәрләрдә зекер әйтеп
Чыныктыр син күңелеңне...

Бик еракта, тирән кое төбеннән чыккан тавыш белән, Фәргать ыңгырашып сорап куйды:

— Син кем, апа?

Баштанаяк бинтка чорналган бу яңа авыруның кинәт кенә татарча эндәшүенә идән юучы хатын сискәнеп китте. Бу бүлмәгә өметсезләрне, үлемгә дучар ителгәннәрне кертеп салалар. Моннан инде алар туп-туры мәетләр бүлмәсенә — моргка китә. Гадәттә, бирегә салган авырулар инде сөйләшә алмыйлар, операциядән соң аңга килә алмыйча, шыпырт кына җан бирәләр. Ә бу бәндә сөйләшеп ята, җитмәсә, татарча! Кулын юып, ул тиз генә авыру янына килде, аның күзләре урынында буш чокыр күреп, чайкалып китте. Ул дөм сукыр иде.

— Мин биредә җыештыручы булам, — диде хатын, аңа кем дип дәшәргә дә белмичә. — Синең исемең ничек, энем?

Тавышыннан ул бу авыруның яшь кеше икәнен чамалаган иде инде, шуңа күрә үзенең олы яшьтәге хатын икәнен сиздерәсе итте.

— Фәргать исемле мин, апа. Ә сезнең исемегез ничек?

— Мин Җәүһәрия апаң булам, энем. Сине бүген генә монда китерделәр, ахры... Бу больницада күптән ятасыңмы?

— Үзем дә белмим инде, апа, — диде Фәргать, чыннан да вакыт хисабын югалтып. — Җәй көне китергәннәр иде, хәзер көз бугай инде.

— Хәзер кыш инде, энем, — диде Җәүһәрия, аны гаять кызганып.

— Моннан чыгу юлы юк икән, алайса, — диде Фәргать, биредә күпме ятуын күз алдына да китерә алмыйча.

— Бөтен җирдән дә чыгу юлы бар, энем, кабердән генә чыгу юлы юк, — диде Җәүһәрия, аны юатасы килеп. — Син исән бит әле, шунысына шөкрана итәргә кирәк.

Ул аннан артыгын сорашмады, чөнки бирегә, гадәттә, карар кешесе булмаган солдатларны яки төрмә әсирләрен китерәләр, алар белән монда эшләүчеләргә артык якынаерга кушмыйлар. Хәер, бу бүлмәгә салганнарның моңа теләге дә булмый, аларның күбесе, аңга килә алмыйча, теге дөньяга китеп бара... Бу татар баласы әнә могҗиза белән терелеп, сөйләшеп ята. Әмма бу вакытлы гына хәл булырга мөмкин, үләр алдыннан бер талпынып алу.

Аның үз милләттәшенә ни белән булса да ярдәм итәсе, бераз булса да хәлен җиңеләйтәсе килде.

— Берәр нәрсә кирәкмиме соң, энем? — диде ул, бүлмәдә беркем дә юклыгына инанып.

— Апа, теге җырыңны тагы җырла әле.

— Җыр түгел ул, энем, мөнәҗәт. Безнең авыл мөнәҗәте.

— Безнеке дә. Миңа картнәй гел шуны көйли иде...

— Кайсы авылдан соң син, энем?

— Татар Караболагыннан мин, апа. Тууым шуннан. Аннан Миасста яшәдек. Монда солдатта хезмәт иттем һәм шушы хәлгә калдым. Ә сез кайсы авылдан?

— Безнең авыл күптән юк инде, энем, — диде Җәүһәрия уфтанып. — Бирдәнештән идем мин. Илле җидедә безне башка урынга күчерделәр. Аннан тагы башка җиргә җибәрделәр, әле урыс арасына, әле буш кырга-далага куып йөрттеләр. Шулай итеп, менә монда килеп эләктек. Безнең авылдан хәзер шушы мөнәҗәтләр генә калды инде.

Җәүһәрия яңадан җырларга уңайсызланды, ахры, Фәргатьнең урын-җирләрен рәтли башлады, чәй алып кереп эчерде. Фәргать тагы, тагы сорап алып эчте, әйтерсең лә ул айлар

буе сусыз торган, әйтерсең лә ул тере суга юлыккан һәм туйганчы эчеп калырга тырыша. Бәлки, милләттәше кулыннан алган бу су аңа шифалы булып тоелгандыр, үз телендә әйтелгән сүзләр җанына дәва булып яткандыр. Үз милләттәше белән бу очрашу аңа караңгы упкын төбендә ятканда югарыдан төшкән бер нур булып тоелгандыр, яшәүгә өмет чаткылары уяткандыр. Ни булса да, бу очрашу очраклы гына булмагандыр, чөнки бу дөньяда очраклы нәрсә юк бит.

Фәргать беренче тапкыр онытылып, рәхәтләнеп күзләрен йомды. Ул әллә йокыга китте, әллә уйланып кына ята — сукыр күзләренә карап белеп булмый иде. Аның колагына яңадан таныш моң — татар моңы ишетелә башлый. Ул әле аны, әбисе булып, кабык арбага салып тибрәтә, әле, әнисе булып, кулларына күтәреп йөртә, Фәргать өчен иң кирәкле, иң газиз сүзләрне әйтә:

Сабыр итик, сабыр итик,
Сабыр коллар сабыр итә.
Сабыр коллар сират күперен
Искән җилләр кебек үтәр.

Сабыр итик, сабыр итик,
Сабыр колдан шайтан качар.
Сабыр коллар җәннәт ишеген
Үз куллары белән ачар...

Җәүһәрия апасы Фәргать янына һәр көн килеп, кереп йөри башлады. Моңа табиблар да сүз әйтмәде, чөнки аларның үзләре өчен дә бу татар егетенең язмышы кызыклы иде. Гадәттә, мондый күләмдә радиация алган авырулар үлә, алар фикеренчә, Фәргать тә инде күптән үләргә тиеш иде. Ә ул һаман яши! Эчендә ярты әгъзалары киселгән, туракланган, каны агуланган, күзе күрми, ә ул һаман тырмаша. Монда эшләүче галимнәр өчен организмның шулай көрәшә алуы кызыклы факт иде һәм алар Фәргатькә үз милләттәше белән иркенләп аралашырга мөмкинлек бирделәр. Чөнки аларның икесеннән дә беркемгә дә зыян килерлек түгел, ә бу татар егетенең фән өчен кирәк булуы бар.

Ә Җәүһәриягә шул гына кирәк иде. Ул Фәргатькә өйдән пешереп ризыгын да, башка кирәк-яракларын да ташый башлады, аны кашыклап ашатты. Бик кызганды ул бу татар баласын. Ул аның кулларына, аякларына әйләнде, яңадан яшәргә өйрәтте. Фәргать аңа әкренләп үзенең серләрен сөйләп бетерде — үз тормышы турында да сөйләде, Гөлҗиһан турында да әйтте. Ул үзенең сукыраюын, авыр хәлдә больницада ятуын беркемгә дә әйтмәгән икән, Җәүһәрия апасыннан да бу серне дөньяга чыгармавын сорады. Әниләре аны Иртәштә өстәмә хезмәткә калган дип беләләр, ә Гөлҗиһан

берни белми. Һәм хәзергә барысы да шул килеш калырга тиеш. Шушы хәленә ияләнгәнче, сукыр килеш тә кеше булып яшәргә өйрәнгәнче, ул якыннары күзенә күренмәячәк. Чөнки аның беркем өстенә дә йөк булып төшәсе килми, беркем кулына да каласы килми. Аның кеше күзенә мескен булып күренәсе килми.

Елга якын Сөнкүл больницасында аунаганнан соң, үзе белән киңәшеп, аны махсус гарипләр йортына урнаштырдылар. Чөнки беренче чорларда Фәргатькә яшәргә урын да, медицина хезмәте дә кирәк иде әле. Иртәштә Фәргать кебек дөм сукырлар, телсез-чукраклар, ятим гарип-горабалар күбәйгәч, алар өчен махсус йорт ачарга булдылар. Караучысыз калган бу авырулар Сөнкүлнең «Б» лабораториясе өчен әзер материал, алыштыргысыз, һәрвакыт кул астында булган тәҗрибә чыганагы иде. Шуңа күрә аларны Берия концлагерыннан ерак җибәрергә теләмәделәр. Гарипләр йортына да шул ук Берия табиблары хезмәт күрсәтә иде. Фәргать тә ихтыяри-мәҗбүри шулар арасында калды. Аңа өр-яңадан яши башларга өйрәнергә кирәк иде.

Гарипләр йорты чагыштырмача яхшы җиһазландырылган, шундый ук медперсонал белән тәэмин ителгән, үз эчке тәртибе белән яшәп ятучы бер дөнья иде. Фәргатьне үзе кебек сукырлар янына урнаштырдылар, даими күзәтеп, карап торырга табибын, санитарын, тәрбиячесен билгеләделәр. Бирдәге сукырларның хәтта аерым оешмалары да бар иде. Әмма Фәргать өчен иң мөһиме — аларны биредә яңадан яшәргә, укырга-язарга өйрәтәләр, белем, һөнәр бирергә тырышалар иде. Һәм Фәргать шушы мөмкинлеккә теше-тырнагы белән чытырдатыпябышты, аның яңадан яктыга, зур тормышка чыгасы килә иде. Һәм ул бер генә мөмкинлекне дә кулыннан ычкындырмаска булды.

Үзе кебек дөм сукырлар арасында яшәү, алар белән даими аралашу Фәргатьне бөтенләй уятып җибәрде.

Бу дөньяда аның кебекләр күп икән бит һәм барысы да яшәү өчен тартыша. Берсе дә үлем көтеп утырмый, киресенчә, өйләнешәләр, гаилә коралар, балалар үстереп яталар. Биредә аксаклар яңадан йөрергә өйрәнә, телсезләр бармаклары белән аңлатып сөйләшә башлый, сукырлар тишек тишеп булса да, укырга-язарга өйрәнәләр. Фәргать гарип кешеләрнең яшәүгә дәртләре көчлерәк икәнлеген аңлады, ул алар арасында тормыштан зарланып, уфтанып утыручыларны очратмады. Монда һәр көн, һәр минут яшәү өчен тиңсез көрәш бара иде. Фәргать тә шул көрәш диңгезенә ташланды. Шушыннан йөзеп чыкса — ул исән кала, үз дигәненә ирешә, көрәш дәрте сүнсә — төпкә китәчәк иде. Тормыш төбенә тәгәрәячәк иде Фәргать, әгәр үз бәхете өчен көрәшмәсә. Һәм ул көрәшергә булды.

Фәргатьнең күзләре күрмәү бер яктан аңа файдага да булды — ул гариплэр йортындагы тере бәхетсезләрне, үзләренең кем икәнлекләрен дә белмәгән диваналарны, үлгәнче Сөнкүл больницасы өчен тәҗрибә куяны булып торачак бичараларны күрмәде. Күрсә, ул үзенең кайда килеп эләккәнен аңлар һәм коты чыгар иде.

Мәһабәт гәүдәле, ирләрчә кырыс матур Фәргатьне үзе кебек сукыр кызларга димләп карасалар да, ул баш тартты. Кара пәрдәнең теге ягында калган Гөлҗиһан, чая Гөлҗиһан, сылу күрше кызы һәр төн аның төшләренә керде, бер генә минутка да яныннан китмәде. Ул кайчагында, хыялга бирелеп, Гөлҗиһан белән гаилә кору, балалар үстерү турында уйлый башлый, аннан табибларның «Балаң булмаячак, булса да, гарип туууы мөмкин» дигән сүзләрен исенә төшерә. Юк, Гөлҗиһан турында онытырга кирәк инде аңа, аны бәхетсез итәргә Фәргатьнең хакы юк. Ә Фәргать белән ул бәхетсез булачак, чөнки сукыр, бөтен җире туракланган, ата булырга ярамаган ир-ат ничек чәчәк кебек кызга бәхет китерсен? Фәргать шулай уйлый иде. Шуңа күрә ул Гөлҗиһанга үзенең дөньяда барлыгын да хәбәр итмәде. Шулай ук башкаларга да якын килә алмады.

Ә әнисе, туганнары белән арасын өзмәде Фәргать...

Үз кулы белән хат яза алмаганга, ул башта аларга телеграммалар суга иде. Аннан, инде йөри башлагач, шушы гариплэр йортына килеп урнашкач, Миасс белән телефон элемтәсен дә урнаштырды. Чөнки аның өчен әнисенең, якыннарының тавышын ишетү бик мөһим иде, алар да, тавышын ишеткәч, Фәргатьнең исән икәнлегенә тәмам инандылар, тынычландылар. Алар ай саен шулай сөйләшеп тордылар, әмма өйдәгеләргә дә Фәргать дөресен әйтмәде, ә алар үзләре ябык шәһәргә кереп, тикшереп йөри алмадылар. «Өстәмә хезмәткә калдым, бәлки, яшәргә дә бөтенләйгә биредә генә калырмын», — диде ул аларга. Фәргать әнисен, туганнарын рәнҗетәсе килмәде, хәтта пенсиясенең бер өлешен дә ай саен аларга җибәреп бара башлады. Җәүһәрия апасы ярдәме белән, ул Миасска посылкалар, күчтәнәчләр салуны да гадәткә кертте. Ай саен улының тавышын ишетеп торган, ярдәмен күргән ана кеше аның кайтмавы белән ризалаша төште. Тормыш тагы шулай үз җаена кереп китте.

Шулай итеп, бер ел үтеп китте, ике, өч ел үтте...

Бу вакыт эчендә Фәргать сукырлар әлифбасы белән яхшы итеп укырга-язарга өйрәнде, Иртәштәге юридик институтка укырга барып керде. Аның мескен гарип булып, дөньяның төбендә яшәп каласы килмәде, бу хәленнән котылуны бары тик гыйлемдә күрде ул. Аның үзе өчен генә түгел, башкалар өчен дә көрәшәсе, бәхетсезләргә ярдәм итәсе килде.

Яшьлек, нәселдән килгән ныклык, олы максатлар белән яшәү каты чирне дә җиңде — ул инде үлем көтеп яткан гарип түгел, ул яшьнәп торган ир-егет иде.

Фәргатьнең яңадан шушы хәлгә килүенә Җәүһәрия апасы да нык булышты, ул аңа әнисен дә, хәтта Гөлҗиһанны да алыштырды. Үзенең ире дә шушындый авырулардан газап чиккән, ахыр чиктә сукыраеп үлгән татар хатыны Фәргатьне үз баласын караган кебек тәрбияләде, гарипләр йортына киткәч тә, арасын өзмәде. Аның үз балалары күптән инде аякка басып, үз гаиләләре белән кайсы Коншакта, кайсы Чиләбедә яшәп яталар иде, шуңа күрә Фәргатькә ул бар җан җылысын бирде. Аның хыялы — Фәргатьне бер яхшы гына татар кызына өйләндерү иде, әмма егет беркем турында да ишетергә теләмәде. Тиң түгеллеген белсә дә, ул бары тик Гөлҗиһан турында гына уйлый, аның хыялы белән генә яши иде...

— Әллә Гөлҗиһанга сиздереп карыйкмы соң монда икәнлегеңне? — дип, беркөнне сак кына сорап куйды Җәүһәрия.

— Юк, юк, апа, бу мөмкин хәл түгел! — дип кабынып каршы чыкты Фәргать. — Ул яшь, сәламәт кыз бала, нигә үзенең гомерен авыру, сукыр кеше белән бәйләргә тиеш ул?!

— Яратса, бәйләр, энем. Мәхәббәтнең үзенең күзе сукыр була аның. Әгәр монда икәнлегеңне белсә, Гөлҗиһаның нишләр дип уйлыйсың?

— Килеп җитә, — диде Фәргать, ике уйлап тормыйча. — Син аны белмисең әле, Җәүһәрия апа, ишетсә, күктән парашют белән төшәчәк ул Иртәшкә, шундый үткен кыз ул.

— Соң, шулай булгач? — диде Җәүһәрия аптырап. — Килсен, күрсен, аннан үзе хәл итәр.

— Ә минем бу хәлдә күренәсем килми аңа, — диде Фәргать, башын иеп. — Мескен хәлдә күренәсем килми. Ул зуррак бәхеткә лаек.

Шушы сөйләшүдән соң Җәүһәрия, Фәргатькә әйтмичә генә, Караболакка аның турында хәбәр җибәрде. Бу хәбәр Таһирҗан карт кулына килеп керде. Дөньяда бер генә очраклы нәрсә дә юк иде шул, кешеләр тәкъдирдә язылганга сәбәпчеләр генә булалар иде.

Укып бетереп, диплом алгач, Фәргать үзе дә Гөлҗиһанга хәбәр салып карарга ниятли иде. Әмма аңа кадәр ерак иде шул әле, ул укуын яңа башлады. Фәргатьнең ишетүенчә, Гөлҗиһан инде Чиләбедә медицина училищесы тәмамлаган. Ул Гөлҗиһанның хәзергә кияүдә түгел икәнлеген дә белә, бөтен күңеле белән аның ашыкмавын, башкага кияүгә чыкмавын теләде. Тик бераз гына көтсен, сабыр итсен иде Гөлҗиһан. Фәргать бу тормышта үз урынын табачак, һичшиксез, табачак! Ул гомер буе гарипләр йортында ятмас, пенсия күзенә карап

тормас, үз гаиләсен алып бара алырлык, башкаларга да ярдәм итәрлек шәхес булыр, Алла теләсә. Тик Гөлҗиһан гына ашыкмасын, дөньяда Фәргать барын онытмасын, сабыр итсен иде.

## Егерменче бүлек

Гөлҗиһан килергә җыенган Иртәш шәһәре алтмышынчы еллар азагына зур бер промышленность үзәгенә әйләнгән иде инде.

Дөрес, 1954 елның мартында аңа рәсми рәвештә, Озерский исеме бирелде, әмма халык телендә ул барыбер башка исемдә йөрде. Кайчандыр бары тик бараклардан һәм җир куышларыннан гына торган бу яшерен шәһәр «База» дип тә, «Десятая площадка», «Челябинск-40», «Сороковка» дип тә, «Почтовый ящик-21», «Челябинск-65» дип тә йөртелә. Хәер, шәһәргә исем бирелсә дә, аның адресы барыбер почта ящигы саны белән атала, шулай языла иде. Озерский исеме аңа, адресларга язылып һәм карталарга төшерелеп, яңадан нибары 1994 елда гына әйләнеп кайтачак әле.

«Маяк» атом комбинатында нинди генә көчле аварияләр булуга карамастан, шәһәр җир астында һәм җир өстендә җәелеп үсүен дәвам итә. 1957 елгы шартлау да инде онытылып бара, беркем «Маяк»ны ябарга җыенмый, чөнки Советлар Союзы үзенең атом чорына әле аяк кына баскан була. Биредә атом-төш коралы җитештерү буенча илдә, хәтта дөньяда тиңе булмаган яңа төр промышленность үсеп чыга. Кыска вакыт эчендә бер-бер артлы дистәләгән атом реакторы сафка баса. Иртәш ярымутравында җир астын тоташы белән атом реакторлары, радиохимик заводлар, радиоактив калдыкларны саклау һәм эшкәртү өчен йөзләгән каберлекләр һәм объектлар төзелә, уран һәм плутоний өстендә эшләү дәвам итә. Ә өстә, берни булмагандай, урманнар шаулап утыра, шәһәр яшәп ята. Аста атом казаны кайный, өстә кешеләр яши.

Гөлҗиһан менә шушы шәһәргә эшкә килергә җыена иде.

Бу чорда инде кешеләр Сталин заманындагы агач бараклардан, җир куышларыннан әкренләп ике катлы кирпеч йортларга күчә башлаган булалар. Хәер, бараклар әле бик озын гомерле булып чыга, алтмышынчы еллар ахырында да анда тормыш кайнап тора, атомчылар яшәп ята. Эш эзләп авылдан килүче яшьләр, юллама белән бирегә җибәрелгән белгечләр исә күбрәк тулай торакларга урнашалар. Тулай торак бүлмәләре икешәр катлы тимер караватлар белән дыңгычлап тутырылса да, барыбер халыкка урын җитми. Соңрак Иртәштә Финляндиядән кайтарылган әзер такта йортлар да күренә башлый, аулак тыкрыкларда аерым агач йорт-

лар үсеп чыга. Соңгыларында шәһәр һәм завод җитәкчеләре көн күрә. Сталин, Берия үлү белән, Иртәштә алар исемен йөрткән урамнар Ленин, Победа исемнәренә үзгәртелә, һәр җирдәгечә, монда да Совет, Пушкин урамнары барлыкка килә. Һәм алтмышынчы еллар азагында Иртәштә «хрущевка» дип аталган беренче панель йортлар күренә башлый, баракның эшче халкы шунда күчә. Шәһәр күзгә күренеп үсә, аны, нигездә, тоткыннар һәм хокуксызлар төзи. Алар коточкыч авыр шартларда, җимерек баракларда, палаткаларда һәм җир йортларда, башка халыктан аерым яшиләр. Аларны эшкә этле конвой белән йөртәләр.

Иртәш «База» дип йөртелгән такта чорыннан чын мәгънәсендә заманча таш шәһәргә әйләнә... Халык үлә тора, туа тора, Иртәштә яңа буын үсеп җитә. Шәһәр үзенең мәдәниятенә, мәгърифәткә, спортка зур игътибар бирә башлый, чөнки яшь буынны таратмыйча тотып тору өчен нәкъ шулар кирәк була. 1952 елның декабрендә биредә Мәскәүнең инженерлык-физика институтының филиалы ачыла, атом белгечләрен шәһәр үзендә әзерли башлый. Кырык яшенә дә җитмичә рактан, нурланыштан үлгән инженер-химиклар урынына сәламәт, яшь буын кирәк була. Шуңа күрә Иртәштә эшли башлаган Көньяк Урал политехникумына ашыгыч рәвештә бөтен ил буенча яшьләрне җыя башлыйлар. Бирегә Горький, Дзержинский, Кинешма, Кострома, Пенза, Рошаль һәм башка шәһәрләрдән ашыгыч рәвештә дүрт йөз егет һәм кызны китерәләр. Алар нибары уналты яшьтән егерме яшькәчә булалар. Һәм алардан тиз арада үлгән атомчылар урынына белгечләр әзерлиләр, аларны ни көтәсен әйтмиләр. 1950—1952 елларда бу политехникумны өч йөз алтмыш бер кеше тәмамлый һәм аларны туп-туры атом казанына озаталар. Һәм бу яшьләр, ун-унбиш ел эчендә атом нурланышы алып, сафтан чыгалар. Совет режимы алар урынына яңа кадрлар әзерли башлый. Атом казаны бер дә буш тормый. Соңыннан техникум белән физика институты бергә кушыла һәм аннан «Маяк» өчен өч мең атомчы белгеч әзерләнеп чыгарыла. 1967 елда, Гөлҗиһан Иртәшкә килгән елны, бу институтны «Маяк»ның булачак директоры Виктор Ильич Фетисов та тәмамлый. Соңыннан ул да баш мие рагыннан үлә.

Иртәштә 1952 елда Маяковский исемендәге кинотеатр эшли башлый, 1953 елның маенда СССР Медицина фәннәре академиясенең биофизика институты филиалы ачыла. 1956 елда — Пионерлар сарае, 1958 елда — «Маяк» мәдәният сарае эшли башлый, 1959 елда «Строитель» мәдәният йорты ачыла. Яшерен атом шәһәре яхшы азык-төлек белән турыдан-туры Мәскәүдән тәэмин ителә, шуңа күрә биредә халык азыкка кытлык кичерми. Ил талоннар белән ризыкка чират

торганда, биредә ите-мае һәм башкасы тулып ята. Шуңа күрә Иртәш халкын тирә-якта «шоколадники» дип йөртәләр, ягъни кәнфит ашап ятучылар.

Шушы чорда инде шәһәр читендә зур зират пәйда була һәм ул бик тиз тула башлый. Башта татарларны урыс зиратының бер читенә аерым күмәләр, әмма ул бик тиз тәреле каберләр чолганышында кала. Зиратлар һәм каберләр бутала, кушыла, бергә әйләнә. Атом барысын да тигезли. Яшьләр моның белән ризалашалар, олы як мәетне татар авылларына алып кайтып күмәргә тырыша. Шәһәрдә татарлар шактый яшәсә дә, анда бер генә татар мәктәбе, татар балалар бакчасы да булмый. Мәчет, милли мәдәният йортлары турында инде әйтәсе дә юк. Татарлар бирегә эшләргә һәм үләргә генә керәләр.

Һәм шушы таш шәһәргә, урыс шәһәренә, атом каласына татар кызы Гөлҗиһан да килә.

Нәрсә көтә аны биредә, монда аның кадерле гомерен дә атом казанына салып кайнатмасалармы, телен, динен оныткан җансыз маңкортка әйләндермәсләрме? Бу хакта әле беркем бернәрсә белми.

Атомчы белгечләрне Иртәшнең үзендә әзерләгән кебек, нурланыш алган авыруларны да читкә чыгармыйча, биредә генә дәвалау юлларын эзлиләр. Шәһәрдә беренче радиация лабораторияләре беренче атом реакторлары белән бергә төзелә. Бу икәүнең һәрвакыт җитәкләшеп йөриячәкләрен илдә белүчеләр була, шуңа күрә, атом объектлары белән бергә, алардан зарар күрәсе кешеләр өчен больницалар да төзи башлыйлар. Һәм, әлбәттә, радиацияне өйрәнү буенча фәнни-тикшерү институтлары. 1950—1953 елларда гына да сигез мең кешенең нурланыш алуы билгеле була, әмма табибларга алга таба бу диагнозны куймаска кушыла. КГБ генералы Ткаченко үз эшен яхшы белә һәм ул дәүләт серен кешеләрдән дә артык саклый.

Шулай итеп, Гөлҗиһан эшкә килгән Иртәш шәһәрендә «радиационная медицина» дип аталган өр-яңа юнәлеш барлыкка килә, анда ил буенча иң көчле белгечләр тартыла. Алар, еллар үтү белән, бу юнәлештә шактый зур ачышлар ясыйлар, төрле дәрәҗәдәге исемнәргә ирешәләр, дәүләт премияләре алалар, һәм, нәтиҗәдә, шул ук чир белән бу дөньядан китеп баралар. Дөнья медицинасы ракны да, нурланыш авыруларын да җиңә алмый, киресенчә, ул аларны җиңә килә.

Иртәштә гарип балалар күпләп туа башлый. Әмма, ни гаҗәп, бу ябык шәһәрдә илленче елларда бала туу ил буенча күрсәткечкә караганда, ике тапкыр күп була! Моны Иртәшнең яшьләр шәһәре булуы белән дә, тормыш шартлары чагыштырмача яхшы булуы белән дә аңлатырга тырышып ка-

рыйлар. Бу хәтле күп бала тууны радиациянең кеше организмына сәер тәэсире нәтиҗәсе булуы мөмкин икәнлеген дә әйтәләр. Чөнки бу шәһәрдә үсемлекләр дә кирәгеннән артык котырып үсә, күлдәге балыклар да кеше буе була.

Шәһәр үз тормышы белән яшәп ята, ә «Маяк»ны әледән-әле көчле шартлаулар, эреле-ваклы аварияләр тетрәтә. 1960 елның 5 декабрендә, СССР Конституциясе бәйрәме көнендә, «Маяк»та зур авария була, эшчеләр көчле нурланыш ала, күпләр үлә. Шәһәр өстенә көчле радиация тарала. Шулай ук 1962 елның 28 февралендә, шул елның җиденче сентябрендә, 1965 елның уналтынчы декабрендә «Маяк»та көчле шартлаулар була, бөтен дөньяга радиация тарала. Алтмышынчы еллар уртасында зур давыл чыгып, атом калдыклары күмелгән Карачай күлен күтәрә, миллионлаган кюри радиоактив матдәләр, үлем болыты булып, шәһәр һәм авыллар өстенә оча... Рәсми мәгълүматлар буенча гына да, бу афәтләр вакытында кырык бер-кырык ике мең кеше нурланыш чире ала. Татар егете Фәргать тә шулар арасында була.

Һәм татар кызы Гөлҗиһан шушы утлы шәһәргә, атом арасына кереп бара иде.

Әкиятләрдәге гүзәл кыз кебек, ул сөйгәнен эзләп, аны коткару өчен аждаһа авызына кереп бара.

Әмма бу әкият түгел, куркыныч чынбарлык иде...

## Егерме беренче бүлек

Гөлҗиһан Иртәшнең капка төбенә килеп басты һәм аптырап туктап калды. Ул аның ябык шәһәр икәнлеген белсә дә, бу хәтле сак һәм күзәтү астында яшидер дип уйламаган иде. Шәһәрне кош та очып керә алмаслык биек таш коймалар урап алган, аларның өстеннән электр токлы чыбыклар үткәрелгән. Ул коймаларның башы да юк, ахыры да күренми, әйтерсең лә каршыда шәһәр түгел, таш төрмә. Койма буйларында да, эчтә дә, тышта да зур-зур этләр йөри, алар һәр нәрсәне килеп исни, һәр кешегә килеп танавын төртә. Этләргә ияреп, сакчы конвойлар йөри, алар да бар нәрсәне капшый, бар нәрсәне тикшерә. Әле шәһәргә кермәгән, әмма инде атлаган саен мылтыклы сакчы очрый, адым саен документлар тикшерәләр.

Медицина училищесыннан Иртәштә эшләргә махсус юлламасы булса да, киләсе алдан хәбәр ителсә дә, Гөлҗиһанны ишек төбендә бик озак тоттылар. Башта аның әйләндерә-әйләндерә бөтен документларын тикшереп чыктылар, аннан бөтен әйберләрен, сумкасын җентекләп актардылар. Иң соңыннан, бер кечкенә бүлмәгә алып кереп, погонлы хатын-

кызлар үзен анадан тума чишендереп, капшый-капшый тентеделәр, чәч толымнарына хәтле сүтеп карадылар. Монысына Гөлҗиһан бигрәк тә гарьләнде, аның әле беркайчан да чит кешеләр алдында болай шәп-шәрә калганы юк иде. Гомерендә дә мондый хәл күрмәгән горур Гөлҗиһанның хурланудан күзләренә яшь бәреп чыкты, ул, берәр усал сүз әйтеп җибәрмәс өчен, иреннәрен тешләде. Аңа хәзер каршы сүз әйтергә дә, болар белән бәхәскә керергә дә ярамый, бигрәк тә — бу этле сакчылар белән. Ул бит үзенең кая килгәнлеген яхшы белде, ни өчен килгәнен дә белә. Аңа бу шәһәрдә Фәргатьне эзләп табарга кирәк. Шуңа күрә Гөлҗиһан бу хурлыкларга түзә, сүз әйтә алмый.

Ишек төбендә шулай ямьсез кылансалар да, шәһәр үзе Гөлҗиһанны шактый тыныч каршы алды, һәрхәлдә, ул бирердә адым саен мылтыклы кешеләрне очратмады. Гөлҗиһан ниндидер куркыныч, утлар очырып торган шәһәрне күрермен дип уйлаган иде, ә бөтенләй башка күренешкә тап булды. Иртәш бик матур, ямь-яшел, җыйнак, чиста бер шәһәр икән. Ул яшеллеккә төренеп утырган матур-матур тәбәнәк өйләр, шул өйләрнең ишек төпләреннән башланып киткән диңгездәй күлләр, күлләр артындагы кара урманнар. Кара сөремгә батып утырган Чиләбедән соң, аңа бу шәһәр, әллә инде сөйгәне бирердә яшәгәнгә, җәннәт почмагы булып күренде. Әмма шәһәр астында җәһәннәм утлары янып торуын, ул ялкынның бөтен дөньяны юк итәргә сәләтле булуын ул әле аңлап бетерми иде...

Гөлҗиһан агачларның бирердә котырып, тармакланып-тармакланып җәелеп үсүенә игътибар итте. Юл читендәге әрекмәннәренә хәтле колач-колач, чәчәкләр күз явын алырлык җете, яфраклар уч төбедәй зур иде. Гөлҗиһан боларның барысы да көчле радиация нәтиҗәсендәге мутация икәнлеген соңрак белер, әмма хәзергә ул аларга исе китеп, гаҗәпләнеп карап йөри. Аны иң сокландырганы — Иртәш күле булды. Күпме ишетте аның турында Гөлҗиһан, ул, чыннан да, диңгез кебек икән. Аның иге-чиге күренми. Яр буйларында, нәкъ Караболактагы кебек, куе камышлар үсеп утыра, алар арасыннан кыр үрдәкләре пырхылдап очып чыга. Якында гына малайлар кармак белән балык каптырып утыралар, күлгә кереп, чумып-чумып та чыгалар. Нәкъ Караболактагы кебек.

Еракта, Иртәшнең теге ярында, күккә шәмәхә төтен ургытып утырган завод торбалары күренә. «Атом бомбасын шушында ясыйлармы икәнни?» дип уйлап куйды Гөлҗиһан, бу дәһшәтле күренешне күзәтеп. Күпме куркыныч сүзләр ишетте ул Иртәш заводлары турында, имеш, алар аждаһа кебек, бөтен җир астына таралып ятканнар икән. Анда кергән кеше чыга алмый икән. Анда кешеләр өстендә коточкыч тәҗрибә-

ләр ясыйлар икән. Әмма барысы да шунда эшкә бара, бөтен гомерен шушы шомлы шәһәр белән бәйли.

Шәһәр урамнарындагы халык Гөлҗиһанга шактый сәер күренде. Аларның күбесе чамасыз тазалар, аякларын чак өстерәп йөриләр. Шул ук вакытта саргаеп кипкән, үтә ябык кешеләр дә очрый. «Бу — авыру билгесе инде, боларда матдәләр алмашыну бозылган, гормоннар дөрес эшләми», — дип уйлап алды шунда ук Гөлҗиһан, медицина училищесында укыганнарын исенә төшереп. Хәер, биредә авыру кешеләрнең күплеген дәреслекләрдән тыш та белергә була иде — бала арбаларында гарип сабыйларны күп очратты Гөлҗиһан. Аларның күбесе дауна чирле, ягъни дивана иде. Бу күренеш аңа бик авыр тәэсир ясады. Тагын үзен уйлады. Фәргатьне искә төшерде һәм авыр сулап куйды. Чиләбедә Галия апасы әйткәннәрнең ул дөреслеген аңлады. Әмма аңа чигенергә юл юк иде инде һәм ул чигенергә теләмәде дә. «Нәрсә булса да була, инде хәзер барысы да Алла кулында», — дип уйлады Гөлҗиһан һәм үзе эшләячәк больницаны эзләп китте.

Шәһәр больницасы ике катлы яңа бинада булып чыкты. Ул Гөлҗиһанга ошады, чөнки мондагы медицина җиһазлары, тәртип бер дә Чиләбенекеннән ким түгел иде, хәтта артык булырга да мөмкин. Чөнки биредә радиацион медицина буенча илнең иң зур белгечләре эшли, Мәскәүдән зур профессорлар килеп тора һәм авырулар өстендә күп тәҗрибәләр үткәрелә иде. Кешеләре дә бик ачык күренә, алар Гөлҗиһанны бик тиз үз итеп, яратып аралаша башладылар. Хәер, Гөлҗиһан үзе дә кешеләргә бик ачык, ягымлы, ярдәмчел кыз иде, ә гадәттән тыш матурлыгы аңа күп ишекләрне ачты. Документларын тапшырып, үзе эшләячәк бүлек белән танышкач, Гөлҗиһан тулай торакны эзләп китте. Анысы да больницадан ерак түгел икән, алар бер ишегалдында булып чыктылар. Гөлҗиһанны дүрт кешелек зур гына бүлмәгә урнаштырдылар, аның бүлмәдәшләре барысы да больницаның шәфкать туташлары иде. Биредә гаиләле кешеләр, табиблар да яши икән, алары инде аерым бүлмәләрдә.

Гөлҗиһан дүрт кешелек бүлмәгә урнашуына да сөенеп бетә алмады, чөнки аны Иртәштә баракларда, палаткаларда торалар, ике катлы караватларда яталар дип куркытканнар иде. Анысы эшче халкы өчен икән. Ә Гөлҗиһан, нәрсә дисәң дә, дипломлы белгеч хәзер, фельдшер, шәфкать туташы. Бу белеме белән ул, теләсә, табибларны да алыштыра ала, чөнки аларны авыл больницалары өчен махсус шулай киң профильле итеп укыттылар. Ул шәһәрне сайлагач, хәзергә шәфкать туташы эшенә дә ризалашты. Насыйп итсә, алга таба укуын да дәвам итәр әле ул, Нурҗамал картнәе хыялланганча, нәселдә бер табиб булыр. Ә хәзергә аның төп максаты — Фәргать-

не эзләп табу. Атом бомбасы ясый торган бу куркыныч шәһәргә ул шуның өчен керде, чөнки эшне ул теләсә кайда таба ала иде. Гөлҗиһанның алга таба язмышы, тормышы Фәргатьтән тора. Әгәр ул һаман Гөлҗиһанны ярата икән, Гөлҗиһан мәңгегә аның белән булачак, аның янында калачак. Фәргать нинди генә хәлдә булса да. Әгәр ул Гөлҗиһаннан бизгән икән, башканы ярата икән, Гөлҗиһан да үз юлын сайлаячак. Бәлки, яңадан Чиләбегә кайтып китәр, бәлки, Коншакка, ә бәлки, Караболакка ук...

Һәм кыз, озак көтмичә, эшкә кереште, ягъни Фәргатьне эзләтә башлады. Әмма — әйтергә генә җиңел — шундый зур шәһәрдә, чит-ят җирдә бер татар кешесен эзләп табарга! Башта Гөлҗиһан үз милләттәшләре арасыннан белештереп карады, Хәбибулла абыйсының биредә яшәүче хатынын — Таифә җиңгәсен эзләп тапты, серне бераз аларга да ачты. Әмма алар берсе дә сукыр татар егетен белмиләр иде, күргәннәре дә булмаган. Әйтерсең лә Иртәштә андый кеше яшәми. Аннан Гөлҗиһан эш арасында шәһәр больницалары буйлап йөреп карады, әмма алардан да Фәргатьне таба алмады. Андый кеше Иртәш больницаларында ятмый һәм беркайчан да ятмаган булып чыкты. Шуннан соң ул милиция бүлекләренә, паспорт өстәлләренә мөрәҗәгать итеп карады, әмма аларда да Фәргать Зөлкарнәев исемле кеше теркәлмәгән булып чыкты.

Шулчак Гөлҗиһанның башына яшен яктысыдай уй килде — тукта, бәлки ул, чыннан да, Иртәштә түгелдер? Чиләбедә Галия апасы да: «Сөнкүлдә түгелме икән ул?» — дигән иде бит! Ә Сөнкүл ул — бөтенләй башка ябык шәһәр, анда керү-чыгу махсус рөхсәт белән, шунда яшәүчеләр һәм эшләүчеләр өчен генә икән. Дөрес, ул Иртәштән ерак түгел, янәшә генә, әмма читләр өчен анда юл ябык. Гөлҗиһан сорашып белде, Сөнкүлдә, чыннан да, халык телендә концлагерь дип аталган больница бар икән. Дөресрәге, ул больница да түгел, ФИБның бер бүлеге, махсус лаборатория, ди. Гөлҗиһан үзе эшли торган больницада табиблардан сорашып шуны да белде — иң өметсез, иң авыр хәлдәге авыруларны Иртәштән шунда җибәрәләр икән. Аннан инде кире кайту юк, ди... Кеше йә үлә, йә үлгәнче шундагы гарипләр йортында яшәп кала, чөнки алар гомер буе шул больница каршында махсус хисапта торалар икән.

Гөлҗиһанның йөрәге шашып, ярсып, өзгәләнеп тибә башлады, ул сизенде — Фәргать шунда иде! Аны да, күзләре сукырайгач, шунда озатканнар һәм ул шунда калган. Аның бу хәлдә беркемгә дә күренәсе, йөк буласы килмәгәндер. Бәлки, ул аннан китә дә алмагандыр. Бәлки, ул хәзер дә шунда газапланып, кеше кулына карап ята торгандыр...

Үзенең Сөнкүлгә болай гына керә алмаячагын аңлагач, Гөлҗиһан телефонга йөгерде. Ул Фәргатьнең, чыннан да, шундагы больницада ятканлыгын белде, әмма ул хәзер аннан киткән иде. Фәргать шәһәрнең гарипләр йортына күчерелгән булып чыкты. Сөнкүлнең милиция бүлегенә шалтыратып, туганы дип алдалап, Гөлҗиһан гарипләр йортының адресын алды, Фәргатьнең бүлмә номерын ачыклады. Хәзер алга таба нәрсә эшләргә кирәклеген уйларга кала иде.

Иң мөһиме — Гөлҗиһан Фәргатьнең исән икәнлеген белде. Ул исән, аның адресы бар, димәк, аны эзләп табарга була. Анда кертмиләр икән, хат язып җибәрергә мөмкин бит. Аннан соң тагы уйлар Гөлҗиһан, әмма бу нәрсәне ачыкламыйча туктамаячак. Фәргатьне эзләп тапканчы, күреп сөйләшмичә, Гөлҗиһан инде туктамаячак иде. Һәм Гөлҗиһан Фәргатькә хат язарга булды. Бу мизгелләрдә ул аның дөм сукыр икәнлеген, бу хатны үзе укый алмаячагын бөтенләй онытып җибәргән иде.

Гөлҗиһан хат язарга утырды һәм куркып, каушап калды...

Нәрсә дип язар соң ул аңа? «Яратам. Сагынам. Көтәм...» дипме? Ә Фәргать күптән инде өйләнгән булса яки башканы яратып йөрсә? Адәм хурлыгына калачак бит Гөлҗиһан. Ул хәзер генә үзенең нинди уңайсыз хәлгә калганлыгын аңлады. Таһирҗан бабай сүзе белән генә чыгып китәргә кирәк идеме икән аңа Иртәшкә, әллә башка юл белән тикшертеп карарга кирәк идеме? Юк инде, юк, Гөлҗиһан алай бүрәнә аша бүре куып ята торган кеше түгел, ул барыбер монда килгән булыр иде, Фәргатьне эзләп табар иде. Хәзер дә артык катлауландырып тормыйча, исәнлекне булса да хәбәр итәргә кирәк. Фәргать акылсыз егет түгел, калганын үзе аңлар. Тели икән — ул да хәбәр бирер, җавап язар, юк икән, юк инде, димәк, барысы да беткән. Хакы Гөлҗиһан өстендә калмый. Ул кыз бала, болай да инде үзенә тиештән арттырып та җибәрде кебек. Мәхәббәт, чыннан да, тау күчерә, диләр шул...

«Исәнме, Фәргать абый, сиңа бу хатны күрше кызы Гөлҗиһан яза, әгәр онытмаган булсаң», — дип, ярым шаярып, ярым җитди рәвештә башлап китте ул үзенең хатын.

Шулай дип язды да туктап калды. Кулындагы каләме кинәт кенә авыраеп калды, йөрәге сулкылдап тибә башлады, күзләренә яшь килде. Аның Фәргатьне өзелеп яратуын, беркайчан да онытмавын, оныта да алмаячагын әйтәсе килде — әйтә алмады. Әллә кызлык горурлыгы, әллә артык оялуы ирек бирмәде, әллә билгесезлек куркытты — ул Фәргатькә өзелеп яратуы турында яза алмады.

«Фәргать, син туй көнендә Караболакка кайтмагач, мин бик үпкәләгән идем, — дип дәвам итте ул, турысын әйтергә

уйлап. — Хәзер инде хәлеңне ишетеп белдем, барысын да аңладым. Ник бу хакта миңа башта ук хәбәр итмәдең? Без синең белән ярәшкән егет һәм кыз идек бит. Мин сиңа чит кеше түгел идем...»

Гөлҗиһанның Фәргатькә аны өзелеп-өзелеп яратуы, еллар буе көтүе турында язасы килде, әмма яхшысынмады. Кызгана яки кылана дип уйлавы бар, Алла сакласын. Фәргать бик тә горур егет иде шул, ул беркайчан кызгандыруга бармаячак, нинди хәлдә дә мескенлеккә төшмәячәк. Гөлҗиһан алдында бигрәк тә. Шуңа күрә һәр сүзне уйлап язарга кирәк, уйный дип уйлый күрмәсен...

«Мин медицина училищесын тәмамлап, Иртәшкә, шәһәр больницасына эшкә килдем, — дип дәвам итте ул, юлламаны бирегә үзе сорап алганын әйтмичә. — Эшемне бик яратам. Тулай торакта бүлмә дә бирделәр, иптәш кызларым бик әйбәт. Монда татарлар да күп яши икән, аралашып, күрешеп торабыз...»

Шулай язды да туктап калды...

Юк, аның бөтенләй башка нәрсәләр турында язасы килгән иде бит! Фәргать туйга кайтмагач, үзенең тилерә язуы турында, көне-төне аны гына уйлавы турында, тилмереп, аннан бер хәбәр көтүе турында язасы килде Гөлҗиһанның, тик яза алмады. Бәлки, ул хәзер бөтенләй башка кешедер инде, Гөлҗиһан аны биш ел күрмәде бит. Ул да хәзер үзгәргәндер, Гөлҗиһан үзе дә бу елларда яңадан туып терелде бит. Олыгайды, җитдиләнде, кырысланды. Әтисенең көтмәгәндә авырып китүе, аннан аяксыз калуы, Гөлҗиһанның үз авыруы турында белүе, авылдашларының күпләп үлүе кайгысы Гөлҗиһанны да вакытыннан элек картайтты. Ул да хәзер дөньяга бөтенләй башка төрле карый. Элеккеге бала Гөлҗиһан, шаян Гөлҗиһан, ут Гөлҗиһан юк инде. Шуңа күрә ул беренче мәхәббәтенә дә хатны бик уйлап, үз-үзен тыеп, зур сабырлык белән язарга тырыша. Ә хисләре барыбер күңелендә кайный, ургый, аларны сүзгә әйләндереп, кәгазь битләренә төшерә башласаң, дәфтәр битенә ут кабар төсле.

«Син башка шәһәрдә яшисең икән, — дип дәвам итте ул, хисләрен чак тыеп. — Иртәштә булсаң, бәлки, күрешер идек... Хәер, мин соңгы вакытта синең тормышыңны белмим, бәлки, инде синең гаиләң дә бардыр. Урынсыз борчыган булсам, гафу ит...»

Шулай дип язды да Гөлҗиһан сулкылдап елап җибәрде. Дәфтәр битенә күз яшьләре тамды...

Чыннан да, әгәр Фәргатьнең инде гаиләсе булса? Ул бит кеше күзе төшмәслек егет түгел, теләсә нинди хәлдә дә үз тиңен таба ала. Ул чагында Гөлҗиһанга, йөрәген учларына кысып, аларның юлыннан читкә китәргә генә кала. Гөлҗи-

һан беркайчан да кеше гаиләсенә кермәячәк, хәтта нинди олы яратуы хакына да. Ул моны бик яхшы белә.

Хатның ахырын ничек тәмамларга белмичә, Гөлҗиһан шактый озак уйланып утырды.

Юк, мондый коры хат җибәрергә ярамый Фәргатькә, ул бит хәзер җан җылысына бик мохтаҗ. Бәлки, ул үзе дә, тилмереп, Гөлҗиһаннан бер хәбәр көтеп ятадыр, бәлки, шул бер җылы сүз аны кабат яшәтер, аякка бастырыр! Ичмасам, җыр белән булса да, күңелендәгесен белдерсен әле, һаман яратуын сиздерсен. Алар авылында егетләр-кызлар мәхәббәтләрен гел шулай җырга салып аңлаталар. Балачактан гашыйк булып, сигез ел яратып йөреп, дөньяда башка беркемгә күтәрелеп карамаган Гөлҗиһанның моңа гына хакы бардыр бит инде.

«Фәргать, хәтерлисеңме, син соңгы тапкыр безнең авылга ялга кайтканда, авылга Чиләбедән үзешчән артистлар килгән иде, — дип дәвам итте Гөлҗиһан, уйлары белән үткәннәргә китеп. — Без ул концертны бергә караган идек. Шунда бер яңа җыр башкарганнар иде. Без аны, тын да алмыйча, тетрәнеп тыңлаган идек. Соңыннан син мине озата кайтканда: «Бик моңлы җыр, сүзләре бик мәгънәле, әмма безнең мәхәббәтебез беркайчан да алай бетмәс», — дигән идең. Сиңа шул җырның сүзләрен исеңә төшерәм:

Син ант иттең, вәгъдә бирдең,
Гомерлеккә яр булырмын, дип.
Арган-талган чакларыңда
Йөрәгеңә ял булырмын, дип.

Таң йолдызым, нишләдең син,
Саф иде бит синең күзләрең?
Истән чыкмый «Өзелеп сөям,
Оныта алмам» дигән сүзләрең.

Ник соң, бәгърем, биргән вәгъдәң
Очып китте искән җил сыман?
Ә мин калдым, ялгыз калдым,
Яфракларын койган гөл сыман...»

Гөлҗиһанның битләренә ут капты, керфек очларында тагы яшьләре тибрәнә башлады. Тагы үксеп елап җибәрмәс өчен, ул хатын тиз генә конвертка салды да калтыранган куллары белән Фәргатьнең адресын яза башлады. Ахырга үзенең тулай торак адресын да язып куйды. Инде ни булса булды — хат китте, сүз китте, хәбәр китте. Инде алдагысы — Алла кулында. Язмышында шулай язылган икән — күрешерләр, бәлки, кавышырлар да. Юк икән, димәк, шулай язган. Бу билгесезлектә Гөлҗиһан беренче адымын ясады. Җавапны Фәргать бирергә тиеш иде.

## Егерме икенче бүлек

Фәргатькә Миасстан килгән хатларны Җәүһәрия апасы укып бирә иде.

Фәргать даими рәвештә әнисеннән хат алып тора, кайвакытта игезәк сеңелләре дә язып җибәрәләр. Ул хәзер аларга җавапны үз куллары белән яза, чөнки сукырлар әлифбасын Фәргать күптән бик яхшы итеп үзләштергән иде инде. Хатны ул әниләреннән дип уйлады, чөнки аңа башка хат язар кеше юк иде. Һәм ул, тәмле-томлыларын кыстырып, Җәүһәрия апасы янына чыгып китте.

Сөнкүл читендәге агач баракта Фәргатьне инде барысы да беләләр, барысы да бик якын итәләр иде. Аны сукыр, бәхетсез кеше дип һич әйтерлек түгел, бөтен рәвешеннән тормыш дәрте бәреп тора. Аның алыптай зур, көчле гәүдәсе, һәрвакыт чиста-пөхтә өс-башы, нур чәчеп торган йөзе, ирләрдә сирәк очрый торган чибәрлеге сукырлыгын да оныттыра, ул килсә, барактагы бөтен кызлар йөгереп каршына чыга. Фәргать тәмле-томлыны барысына да җитәрлек итеп алып килә, һәрберсенә нәрсәдән булса да өлеш чыгара. Аннары алар Җәүһәрия апасы белән, озаклап чәй эчә-эчә, хат укый башлыйлар, дөнья хәлләрен сөйләшеп утыралар...

— Бу юлы әни хатны бер-бер артлы җибәргән әле, ашыгыч әйтер сүзе бар, ахры, — диде Фәргать, Җәүһәрия апасы белән кочаклашып күрешкәннән соң.

— Әниең янына бер кайтып килергә кирәк инде, улым, — диде Җәүһәрия, аның аркасыннан сөеп. — Ана бит, исән чакта күрешеп калырга кирәк, дөньянықын белеп булмый.

Җәүһәрия апасы бу хакта аңа килгән саен әйтә, тик Фәргать Миасска кайтуын нишләптер һаман суза. Бу юлы ул исә нигәдер тиз килеште.

— Әйе шул, Җәүһәрия апа, үзем дә шулай уйлап торам, — диде ул. — Хәзер инде укулар башланды, көн саен Иртәшкә йөрисе. Менә кышкы каникулга чыгыйк инде, кайтып та килермен, Алла боерса.

Бу очрашуның тагы да тиз буласын, әмма әнисе белән Миасста түгел, Караболакта очрашасын Фәргать үзе дә белми иде әле.

Иялэнгән гадәт буенча, Җәүһәрия апасы хатны карап та тормыйча ачып җибәрде һәм күзлеген киеп, кычкырып укый башлады.

— «Исәнме, Фәргать абый», — диде дә төртелеп туктап калды. — Бәй, әниеңнән түгел бит бу хат, — диде ул, ни әйтергә белми аптыраганнан.

Аның каушавы Фәргатькә дә күчте, ахры, ул кинәт карлыгып киткән тавыш белән сорап куйды:

— Кемнән соң?.. Миңа башка язар кеше юк бит.

— «Сиңа бу хатны... күрше кызы Гөлҗиһан яза...» — дип укуын дәвам итте Җәүһәрия һәм, шатланып, кычкырып җибәрде: — Гөлҗиһаннан бит бу хат, энем! Гөлҗиһаннан, кәләшеңнән! Менә могҗиза, менә Алланың рәхмәте!

Хатның, чыннан да, Гөлҗиһаннан булуына Фәргать әле ышанып бетми иде. Ничек инде аннан булсын, алар бит инде биш ел аралашмыйлар, Гөлҗиһан аның адресын белми, ә Миасста әнисенә беркемгә бирергә кушылмаган. Ничек инде Гөлҗиһаннан булсын?

Фәргать ап-ак булып агарынып, тетрәнеп, телсез-өнсез калган иде. Ул хатка үрелде, дерелдәгән бармакларын кәгазь буйлап йөртеп, нидер белергә, танырга тырышты. Әйтерсең лә шушы дәфтәр битеннән ул кемнедер эзли, табарга азаплана. Ул хатны күрмәгән күзләренә якын китерде, битләренә куйды, сулышына сеңдерергә тырышты...

— Гөлҗиһан... — дип пышылдады ул, кинәт кенә кибеп киткән иреннәре белән. — Укы, Җәүһәрия апа, таныдым мин — чыннан да, Гөлҗиһанның хаты бу. Укы тизрәк.

Фәргать инде нәрсә ишетергә дә әзер иде.

Гөлҗиһан аның хәлен беләме, юкмы, һаман яратамы, әллә инде онытканмы, ул биш елдан соң Фәргать белән исәнләшәме, әллә бәхилләшәме, саубуллашамы — ул инде барысын ишетергә дә әзер иде. Ул дөньяда менә шушы мизгел өчен генә яшәгәнен аңлады, аның исән калуы да, яшәве дә, үткәне дә, киләчәге дә бары тик Гөлҗиһан белән генә бәйле иде. Бу дөньяда Фәргатьнең башка шатлыгы да, өмете дә, максаты да юк икән.

Ул Җәүһәрия апасы укыган һәр сүзне йөрәге белән йотып тыңлады. Гөлҗиһанның һәр сүзеннән зур мәгънәләр эзләде, сүз араларына яшерелгән сөю хисләрен көтте. Гөлҗиһанның хаты шактый коры кебек тоелса да, нииндидер әйтеп бетермәгән моң, сагыш сизде Фәргать бу сүзләрдә. Ул Гөлҗиһанның һәр сүзен Җәүһәрия апасы артыннан эченнән генә кабатлап барды, мәңге онытмаска йөрәк түренә салып куйды.

Аны бигрәк тә хат ахырындагы җыр тетрәндерде.

Юк, ул аны җыр итеп түгел, Гөлҗиһанның үз сүзләре, әрнүе итеп кабул итте. Аңа еллар аша, Караболакның карлы бураннары аша, Урал таулары аша Гөлҗиһан үзе тилмереп дәшә иде. Бу сүзләр Фәргатьнең күңелен кышкы аҗаган булып яктырта, язгы саф җилләр булып уята, өметләндерә, Гөлҗиһан булып үпкәли, көтә, чакыра иде.

Син ант иттең, вәгъдә бирдең,
Гомерлеккә яр булырмын, дип.
Арган-талган чакларыңда
Йөрәгеңә ял булырмын, дип...

Әйе, алар да бер-берләренә нәкъ шулай дип вәгъдә бирешкәннәр иде бит. Язмыш нинди генә булса да, бер-берләреннән аерылмаска сүз биргәннәр иде. Кая китте ул вәгъдәләр? Нигә алар бүген тормыш ярының икесе ике ягында, нигә алар арасында яралы язмыш, мәңгелек караңгылык соң? Нигә аларның яшьлек хыяллары чәлпәрәмә килде, вәгъдәләре утка очты. Атом утында дөрләп янды. Дөрләп янды?!

Ник соң, бәгърем, биргән вәгъдәң
Очып китте искән җил сыман?
Ә мин калдым, ялгыз калдым,
Яфракларын койган гөл сыман.

Димәк, Гөлҗиһан да ялгыз...

Гөлҗиһан һаман аны көтә...

Һаман ярата...

— Энем, Гөлҗиһан сине һаман ярата бит!

Җәүһәрия апасының сүзләре аңа әллә кайлардан — Урал таулары артыннан ишетелә кебек тоелды.

— Ярата ул сине, — дип дәвам итте Җәүһәрия апасы, Фәргатьнең үзеннән дә артык сөенеп. — Ярата, әмма бу хакта әйтергә уңайсызлана, кыз бала бит. Шуңа күрә җыр белән язып җибәрергә уйлаган.

— Ул минем сукырайганны беләме икән соң? — дип кинәт кенә сорап куйды Фәргать.

Артык хисләнеп китеп, ул моңа бөтенләй игътибар итмәгән иде. Бәлки, Гөлҗиһан аның дөм сукыр калуын, гарипләнүен белмидер? Аны элеккеге таза, көчле Фәргать дип күз алдына китерәдер?

— Шул төшен яңадан укы әле, Җәүһәрия апа, — диде ул, бозлы суга чумарга әзерләнгәндәй.

«Фәргать, — дип, хатны яңадан укуын дәвам итте Җәүһәрия. — Син туй көнендә Караболакка кайтмагач, мин бик үпкәләгән идем. Хәзер хәлеңне ишетеп белдем. Ник бу хакта миңа башта ук хәбәр итмәдең? Без синең белән ярәшелгән егет һәм кыз идек бит. Мин сиңа чит кеше түгел идем...»

Хатта Фәргатьнең авыруы турында башка сүзләр юк иде.

«Хәлеңне ишетеп белдем» дигән. Нинди хәл турында әйтә икән ул, аның сукыраюын беләме икән? Каян белде икән?

— Белгән, энем, белгән, барысын да белеп язганга охшый Гөлҗиһан, — диде Җәүһәрия, Фәргатькә ярдәмгә килергә теләп. — Йә авылыгыздан берәрсе сине Иртәштә күреп кайтып әйткәндер. Монда Караболаклар күп, дисең бит.

— Гөлҗиһан үзе дә Иртәштә икән бит, — дип, аның фикерен дәвам итте Фәргать. — Укып бетереп, Иртәшкә килгән. Ахрысы, чыннан да, язмыш бу.

— Сезгә очрашырга кирәк, энем, — диде Җәүһәрия, егет

киресен уйлап куйганчы. — Алла биргән очрак инде бу. Кыз бала сине үзе эзләп тапкан, инде җавапны син бирергә тиеш.

— Тукта, Җәүһәрия апа, адресы бармы соң аның? — дип сорап куйды Фәргать, борчулы тавыш белән.

Җәүһәрия конвертны әйләндергәләп карады, аннан, балалар кебек, шатланып кычкырып җибәрде:

— Бар, энем, бар. Менә... Иртәштә... Больница поселогында тора икән. Совет урамы, 14 нче йорт, 15 нче бүлмә, дигән. Ханова Гөлҗиһан, дигән...

Ханова. Кыз фамилиясе, үз фамилиясе. Димәк, Гөлҗиһан да ялгыз, кияүдә түгел. Бәлки, чыннан да, Җәүһәрия апасы хаклыдыр, бу — Аллаһ биргән мөмкинлектер? Бәлки, язмышында шулай язылгандыр. Фәргать үзе дә Гөлҗиһанны эзләп табу, аның белән очрашу уе белән яшәде бит. Тик аның бу кыяфәтендә Гөлҗиһанга күренәсе килмәгән иде. Ул, могҗиза көткәндәй, күзләре ачылуны, яңадан күрә башлавын көтте. Әмма караңгылык таралырга ашыкмады. Ә гомер үтә торды. Фәргатькә дә инде егерме җиденче яшь. Нәрсә булса да хәл итәргә, ни булса да эшләргә кирәк иде.

Һәм Фәргать тәвәккәлләргә булды.

Иртәшне ул яхшы белә, Совет урамын, больница бистәсен дә яхшы хәтерли, армия хезмәте вакытында үзләре төзеде алар аны. Ике катлы тулай торакларны да хәтерли. Алар барысы да үзәктә, Фәргать укый торган институттан ерак түгел. Тапмаса, ярдәм итәрләр. Фәргатьне мәсьәләнең ул яклары бөтенләй борчымый иде, чөнки аның өчен күз күрмәү әле ул дөнья бетү түгел. Кайда да кешеләр яши, үзең әйбәт булсаң, ярдәмнәреннән ташламыйлар. Фәргать өчен хәзер иң мөһиме — Гөлҗиһан күзенә күренү иде. Аның Гөлҗиһанга мескен булып күренәсе килми, ул анда үзенә карата кызгану хисе уянуын теләми иде. Яратуны кабул итә Фәргать, ә кызгануны — юк. Шуңа күрә Фәргать бу очрашуны шулай елларга сузды инде, Гөлҗиһанга үзе турында хәбәр бирергә ашыкмады. Бу хәлендә күреп, гайрәте чигәр дип тә курыкты. Ә ул әнә барыбер эзләп тапкан. Димәк, тәкъдирләрендә шулай язылган булган. Хәзер инде төп сүзне Фәргать әйтергә тиеш. Аны кабул итү-итмәү исә Гөлҗиһаннан тора. Аның язмышын хәзер ул хәл итә.

## Егерме өченче бүлек

Гөлҗиһан ул төнне төшендә Фәргатьне күреп уянды...

Матур җәй көне икән, алар Фәргать белән Караболак болынында җитәкләшеп йөриләр... Болын шулхәтле матур, әйтерсең ул башка дөньядан. Нурлы болын өстендә аллы-гөлле рәшәләр уйнап тора, дөньяда булмаган хуш исләр килә.

Фәргать белән Гөлҗиһан болын буйлап атлап түгел, очып баралар икән, аларның аяклары җиргә тими дә. Яннарында — берсеннән-берсе матур балалары, алар да әти-әниләре белән бергә оча. Менә алар шулай оча-йөгерә Аллакүл буена килеп җитәләр. Гөлҗиһан Фәргатьнең бит-күзләрен тау куышыннан агып чыккан чишмә суы белән юа... «Бу — Алып Адәм заманыннан калган тере су, ул безгә ярдәм итәчәк», — ди икән. Гөлҗиһан үзе дә, балалары да шул суда юыналар. Аларның йөзләре, тәннәре тоташ нурга әйләнә бара икән. Менә алар берзаман бөтенләй күзгә күренмәс булалар, болын өстендәге рәшәгә кушылып, җил булып, Караболак өстеннән очып үтәләр. Алда — күз явын алырлык көчле яктылык, ул Фәргать белән Гөлҗиһанны, аның нурга әйләнгән балаларын үзенә тарта, үзенә чакыра икән. Алар, шул яктылыкка кереп, эреп юкка чыгалар, Караболак өстендә аларның саубуллашкан авазлары гына эленеп кала. Алар артыннан күктән җиргә салават күпере сузылып төшә.

Гөлҗиһан әсәрләнеп уянып китте.

Болын, Фәргатьнең нурлы йөзе, берсеннән-берсе матур балаларның алар янында очып йөрүләре аны шулхәтле тетрәндергән иде, ул аларны яңадан күрергә теләгәндәй, тагы күзләрен йомды. Гөлҗиһанның әле беркайчан да бу кадәр матур төш күргәне юк иде. Ә балалары нинди матур! Йөзләре нинди нурлы аларның. Аннан алар барысы да тоташ нурга әйләнеп юкка чыктылар. Күктән иңгән яктылыкка кереп югалдылар. Әйтерсең лә алар алдында күк капусы ачылды.

Төш бик мәгънәле һәм яхшы иде.

Ул Гөлҗиһанга нindидер хәбәр буласын белдерә иде.

Ә Гөлҗиһан бары тик бер генә хәбәр көтә хәзер — Фәргатьнең җавабы. Ул Гөлҗиһанның хатын алгандыр инде, барыбер нидер җавап бирмичә калмаячак. Төшеннән күренгәнчә, яхшы хәбәр көтә Гөлҗиһан. Шатлык көтә. Аның моңа хакы бар бит инде. Әгәр Фәргатьнең гаиләсе булса, ул Гөлҗиһанга җавап та биреп тормас. Ул аның өчен кайчандыр авылда җитәкләшеп йөргән күрше кызы гына булып калачак. Әгәр ялгыз булса, ул Гөлҗиһанны эзләп табачак. Ул Фәргатьне белә. Яратуы хак икән, ул ут эченә дә керәчәк. Ут эченнән дә үзенә кирәкне алып чыгачак.

Шулчак Гөлҗиһанның йөрәге жу итеп китте.

Тукта, ул хат язды язуын, ә Фәргать укый алмый бит! Күрми бит ул! Димәк, ул Гөлҗиһанның хатын укымаган. Ә ул тилмереп җавап көтеп ята тагы. Ә бәлки, ул берәрсеннән укыткандыр дигән зәгыйфь кенә өмет чагылып китте кызның күңелендә. Анда татарлар булмыйча калмас, Фәргатьнең аңа гына башы җитәр...

Тормыш чынбарлыгы матур төшне каплап китте.

Фәргатьнең сукыр икәнлеген Гөлҗиһанның исенә төшерде...

Гөлҗиһан барыбер бу төшенә рәхмәтле иде, ул әле шактый вакыт шуның хатирәләреннән җылынып йөрде.

Бүген — ял көне, кызларның кайсылары авылга кайтып киткән, кайсылары шәһәрдә йөри. Гөлҗиһан авылга теге атнада гына кайтып килде, әниләренә бәрәңге алырга булышты. Таһирҗан бабасына да алып бирде. Караболакта барысы да искечә бара, яз җитсә — бәрәңге утырталар, көз җитсә — казып алалар. Халык авырый тора, үлә тора, туа тора, бу хәлләренә инде ияләнгәннәр. Гөлҗиһанның әтисе чуен аяклары белән дөбердәтеп эшләп йөри, авыл халкы урын өстендә ятарга яратмый шул ул. Иртәш больницаларында, аптекаларда дару күп, бик яхшылары да бар, Гөлҗиһан авылдашлары өчен дә ташый башлады аларны. Күп булмаса да, терелтә алмаса да, бераз авыртуларын киметә, сызлануларын бастыра. Моңарчы табиблар тарафыннан бер игътибар да күрмәгән авыл халкы Гөлҗиһанга рәхмәтләрен әйтеп бетерә алмый, язып, заказ биреп җибәрәләр. Бу юлы күршеләре тын буылганнан дару сорадылар, ә ул бик сирәк була. Гөлҗиһан аны Иртәшнең дежур аптекасында бар икән дип ишеткән иде, шуннан алып куярга булды. Ә классташы Рәшидәгә исә кайткан саен «төймә» кирәк. Баш даруын ул шулай атый. Һәм Гөлҗиһан аны авылга кайткан саен алып кайта, Рәшидә исә моңа балалар кебек сөенә.

Гөлҗиһан җиңел генә киенде дә аптекага барып кайтырга булды.

Шәһәрдә алтын көз иде...

Иртәш урамнарына сары яфраклар түшәлгән, алар җилдә салмак кына кыштырдап, хәбәр биреп яталар. Күл буендагы урманнар ут капкандай кызарып, янып утыралар — аларны да көз шундый төскә керткән. Баш очыннан, моңлы кычкырып, торналар үтеп бара. Алар Караболак ягыннан Чиләбегә таба очып үтәләр, аннан тагы да көньякка, җылы диңгез буйларына китәрләр. Иртәш суында зәңгәр күк, ак болытлар, торналарның кара шәүләләре чагыла.

Гөлҗиһанның йөрәге дерт итеп китте...

Бүген — 29 сентябрь, Иртәштә шартлау булган көн иде...

Моннан ун ел элек тә нәкъ шушындый матур көзге көн иде бит.

Алар бөтен авыл белән Караболак кырында бәрәңге алалар иде. Кичке якта Иртәш ягындагы көчле шартлаудан җир сикереп куйды, күк ярылгандай булды, дөнья караңгыланып китте. Аннан Иртәш өстендә утлы төтен баганасы күтәрелде, Уралтау тирәләрендә аҗаган уйный башлады, Караболак өстенә соры томан килгәне күренде. Бу — атом болыты шулай

үлем алып килә икән. Гөлҗиһан үзенең күрми башлавын, кан косып егылганын хәтерли. Аны авылга атка салып алып кайтканнар иде. Ул вакытта Фәргать тә әтисе белән Караболакка килгән иде.

Аннан соң да инде ун ел вакыт үткән. Ул вакытта атом утыннан янган агачлар урынында инде яңалары үсә. Җимерелгән биналар урынына башкаларын төзегәннәр. Атомнан агуланган шактый авылларны башка урынга күчергәннәр. Караболак шул үле зонада утырып калган. Һәм аларның бөтен авырулары да менә шуннан булырга тиеш. Әмма бу хакта кемгә әйтәсең, кемне ышандырасың, бөтенесе беравыздан киресен сөйләп торганда?

Гөлҗиһан, кирәкле даруларын алып, кайтыр якка борылды.

Борылуга, туп-туры үзенә каршы килгән алыптай гәүдәле ир-атны күреп, баскан урынында катып калды.

Иртәш урамын тутырып, бер кочак чәчәкләр тотып, аңа таба Фәргать атлый иде.

Аңа җитәрәк, ул нидер сизенеп, туктап калды, аның кара күзлекләрендә Гөлҗиһан үзенең чагылышын күреп, тетрәп китте. Йөрәгеннән, сагыну, сызлану авазы булып, Фәргать исеме бәреп чыкты. Бу тавышны Фәргать җиде кат җир астыннан, җиде кат күктән ишетсә дә таныр иде. Аның каршында Гөлҗиһан үзе басып тора иде.

— Гөлҗиһан... — диде ул, тавышы калтырап китте. — Менә мин килдем, Гөлҗиһан...

Аяк астындагы сары яфракларга җан керде, алар җырлап, Гөлҗиһан белән Фәргать тирәсендә бөтерелә башладылар.

Күктә очып барган торналар, Иртәш өстенә төшеп, Гөлҗиһан белән Фәргатькә көмеш каурыйларын калдырып киттеләр...

Урал тауларыннан искән көзге җил аларны зәңгәр күкләргә алып менеп китте, кочагында тибрәтте, җаннарын иркәләде.

Бөтен дөнья шатлыгыннан шашты, чөнки бүген Гөлҗиһан белән Фәргать очрашкан иде.

— Әллә көтмәгән идеңме, Гөлҗиһан? — диде Фәргать, аның кайнар кулларыннан кысып.

— Көттем... — диде Гөлҗиһан, күз яшьләрен җилләр иркенә биреп.

Икесенең дә күңелендә янар таулар кайный, бу мизгелләрдә сүзләр көчсез, фикерләр таркау иде. Алар шулай, җитәкләшеп, Гөлҗиһан яши торган тулай торакка керделәр, бүлмәгә үттеләр. Кочагындагы чәчәкләрне алган булып, терсәгеннән җай гына тотып, Гөлҗиһан Фәргатьне түрдәге урындыкка алып килеп утыртты. Якыннан ул аның йөзенең шактый олыгайганын күрде, әмма андагы нур, кырыс матурлык теләсә кемнең башын әйләндерерлек, телсез калдырырлык иде. Анда Йосыф пәйгамбәр матурлыклары бар иде.

— Хатыңны алдым, Гөлҗиһан, — дип башлады Фәргать сүзен турыдан. — Менә, сорауларыңа җавап бирергә үзем килдем.

— Бәлки, башта чәй эчеп алырбыз, Фәргать? — диде Гөлҗиһан, үзен аның белән ничек тотарга белмичә.

Ул аннан тартына да, ул аңа тартыла да, аның Фәргатькә ярдәм дә итәсе килә, әмма бу хакта аңа сиздерәсе дә килми иде. Алар арасында әле ниндидер киеренкелек бар, артык җитдилек бар иде. Шуңа күрә Гөлҗиһан тизрәк чәй эчәргә тәкъдим итте, Фәргать моңа тизрәк риза булды.

— Куй алайса, Гөлҗиһан, — диде ул, гап-гади итеп. — Караболактагы кебек, бер гөрләшеп чәй эчеп алыйк...

Караболак сүзен ишеткәч, Гөлҗиһанның йөрәге тагы кысылып, сулкылдап куйды.

Фәргать, ялга кайтканда, Гөлҗиһанның әбиләрендә туктый иде. Гөлҗиһан шунда кереп, Фәргатьне үзе чәй куеп сыйлый иде. Өстәлне дә үзе әзерли, чәйне дә Фәргатькә үзе ясап эчерә, үзе исә аның каршында утыра. Ярәшелгән егет белән кыз булгач, әби-бабалары бу хәлгә тыныч карыйлар, яшьләр өчен куанып бетә алмыйлар. Аның исеме генә чәй эчү иде инде, алар сәгатьләр буе шулай бер-берләренә карап, бер җан булып, серләшеп утыралар иде.

— Әти-әниләрең, әби-бабаларың ни хәлдә, Гөлҗиһан? — дип сорады Фәргать, шул татлы мизгелләрне исенә төшереп. — Моннан кайтып йөри аласыңмы?

— Аллага шөкер, барысы да исән-саулар, — диде Гөлҗиһан, сүз башларга сәбәп табылганга сөенеп. — Әле узган атнада гына кайтып килдем авылга. Бәрәңгеләр алдык, өйдә дә, Таһирҗан бабайларда да.

Шулай сөйләшә-сөйләшә чәй эчә башладылар, Караболак хәлләрен искә төшереп чыктылар. Әмма иң мөһим, иң кирәкле сүзләр әле әйтелмәгән иде, алар аңа ничек тотынырга да белмәделәр. Фәргать үзен гади тотарга тырышса да, аның чынаяк тоткан кулы калтырап-калтырап китә, өстәл өстенә үрелгәндә, ул үзенә кирәк әйберне таба алмый интегә иде. Моны күреп, Гөлҗиһанның йөрәге өзгәләнде, әмма ул үзендәге кызгану хисен басарга тырышты. Аңа бу хәлләргә инде ияләнергә, кызганганын Фәргатькә сиздермәскә, сиздермичә генә ярдәм итәргә өйрәнергә кирәк иде.

Гөлҗиһанның бәхетенә, төп сүзне Фәргать үзе башлады:

— Син минем нигә туйга кайтмавымны аңлагансыңдыр инде, Гөлҗиһан? — диде ул, чынаягын өстәлгә куеп.

— Анысын аңладым, тик соңыннан ник бер хәбәр бирмәвеңне аңлый алмадым, — диде Гөлҗиһан, үпкә-әрнүләрен сиздермәскә тырышып.

Фәргать бераз дәшми торды. Бу кыяфәттә күренәсем кил-

мәде, дип тә әйтәсе килмәде аның. Иң дөресе — ул беркемгә дә йөк булырга теләмәде, хәтта газиз анасына да. Фәргать башта аякка басарга теләде, күзләре ачылуга өмет итте.

— Минем беркемгә дә йөк буласым килмәде, Гөлҗиһан, — диде ул. — Хәтта туган анама да.

— Әниең дә бу хәлеңне белмиме? — диде Гөлҗиһан тетрәнеп.

— Берсе дә белми. Синнән кала... Син каян белгәнсеңдер, күрше кызы...

Гөлҗиһан аны еллар буе өзелеп көткәнен, исән икәнлеген белгәч, бирегә эшкә килүен әйтеп тормады. Иртәшкә килгәч, Фәргатьне күпме эзләткәнен дә әйтмәде. Алар авылында, алар нәселендә кызлар егетләргә башлап мәхәббәт сүзләрен әйтмиләр, янып үлсәләр дә, ир-атның башлавын көтәләр. Гөлҗиһан бит әле аның ялгызмы-түгелме икәнлеген дә белми. Һәм ул монысын туп-туры сорарга булды, чөнки гаиләсе булса, Гөлҗиһан аның белән алга таба мөнәсәбәтләрен дәвам итә алмый иде.

— Ә син ялгызмы, Фәргать? Гаиләң юкмы?

— Юк, Гөлҗиһан, гаиләм юк, ялгыз мин. Синең кебекне очрата алмадым. Ә син?

— Мин дә ялгыз. Мин сиңа вәгъдә биргән идем бит. Без инде ярәшелгән идек.

«Сине генә көттем, сине генә яраттым, һаман сине генә яратам», — дип әйтә алмады Гөлҗиһан. Телләре ул хакта әйтмәсә дә, күңеле, күзләре бу турыда кычкырып тора иде.

Бу сөйләшү шулай өзек-төтек күпме дәвам итәр иде, ул арада шаулашып бүлмәдәш кызлары килеп керделәр. Түрдә Гөлҗиһан белән чәй эчеп утырган чибәр егетне күреп, алар телсез калдылар. Егет пәһлевандай зур гәүдәле, аннан көчгайрәт ташып тора. Йөзендәге нурдан, матурлыктан күз камаша, затлы кара күзлеге дә үзенә бик килешеп, серле төс биреп тора. Кичләрен дә бер җиргә чыкмаган, бер ир-атка күтәрелеп карамаган Гөлҗиһанның менә нинди ханзадәсе бар икән бит! Менә кем өчен саклаган ул үзен. Гөлҗиһанның уттай янган йөзен күрүгә, алар бөтенесен дә аңлап алдылар, ярым шаярып, ярым чынлап, бу чибәр егетнең кемлеген сорый башладылар.

— Ә бу минем ярәшелгән егетем Фәргать була, — диде Гөлҗиһан, ничек бар, шулай итеп.

Аның бу туры җавабыннан Фәргать тә, бүлмәдәге кызлар да башта югалып калдылар. Аннан кызлар, берсен-берсе уздырып, Гөлҗиһан белән Фәргатьне котларга тотындылар.

— Ә туй, туй кайчан була? — дип сорады үткен украин кызы. — Минем Гөлҗиһанның туенда ут чыгарып биисем килә.

Туй?

Гөлҗиһан белән Фәргать, аптырашып, бер-берләренә караштылар. Алар бит туй турында кузгатмадылар. Фәргатьнең уңайсызланып калганын күргәч, Гөлҗиһан сөйләшүне тизрәк шаяруга борып җибәрде:

— Язган булса, туй да булыр, кызлар, биерсез дә, — диде ул, уенын-чынын бергә. — Без әле ул турыда сөйләшмәдек, менә сез кайтып кердегез бит. Ә хәзер менә Фәргатьнең күчтәнәчләреннән авыз итегез.

Кызлар, көлешеп, кияү күчтәнәче дип, өстәл өстенә ябырылдылар.

Ә күчтәнәчләр бик күп иде, каян шулхәтле белеп алган боларны Фәргать? Ул ак күбектән генә торган иң яхшы тортлар дисеңме, затлы конфетлар, тәлгәш-тәлгәш йөзем, алмахөрмә дисеңме, әллә нинди татлы ризыклар, тәмле җимешләр. Бу хәтле нигъмәтне берьюлы бу кызларның бары тик киноларда гына күргәне бар. Алар, көлешә-көлешә, өстәл өстен бушата башладылар, үзләре ара-тирә Фәргатькә дә күз салып алалар. Аның бүлмәдә дә кара күзлектән утыруыннан алар нидер сизенделәр, әмма Фәргать үзен бик гади һәм иркен тоткач, аның сукырлыгын оныттылар. Сөнкүлдән көн дә килеп, институтта юристлыкка укып йөрүен дә белгәч, ул алар каршында бөтенләй үсеп китте. Фәргать, чыннан да, теләсә нинди компаниядә сүзне оста алып барырлык мәдәниятле кеше, җор телле егет иде. Гөлҗиһан аңа читтән генә карап сокланып утырды, аның белән горурланды, Фәргатьнең югалып калмавына, бик тиз үз кешегә әйләнеп китүенә куанды.

Чәй тәмамлангач, өстәл өсте шактый бушый төшкәч, ул Фәргатьне җай гына култыклап алып, озата чыкты. Таныш булмаган урында ул Фәргатьнең читенсенеп йөрүен теләмәде. Шаярып кына башланган сүзгә дә нокта куясы бар иде. Кичке Иртәш аларны җемелдәп торган утлары, Урал ягыннан искән саф җилләре, тормыш шау-шуы белән каршы алды. Бу шәһәр инде Гөлҗиһанга дөньяда иң матур урын булып күренә башлады, чөнки биредә Фәргать бар иде. Ул, үзе дә сизмәстән, култыклаган уңайга, Фәргатькә сыена төште. Фәргать аның кайнар беләген үзенә кысты һәм инде беркайчан да җибәрмәде. Шулай бер-берләренә сыенып, алар кичке шәһәр урамнары буйлап озак йөрделәр. Кая баруларын да ачыкламадылар, ни өчен болай йөрүләренә дә хисап бирмәделәр. Сөйләшмәделәр дә, чөнки бу мизгелләрдә хәтта сүзләр дә артык иде. Алар бер-берләренең җан җылысына, тән җылысына сусаганнар иде, һәм бер-берләренә никадәр газиз, кирәкле икәнлекләрен алар шушы мизгелләрдә аңладылар. Алар бер-берләрен һаман яратуларын, бер-берләреннән башка тора алмауларын аңладылар.

Шулай итеп, язылышуны һәм кечкенә генә туй мәҗлесен Иртәштә уздырырга, ә никах мәҗлесен Караболакта үткәрергә булдылар.

Фәргатькә бик сиздермичә генә, бу мәшәкатьләрнең барысын да Гөлҗиһан үз өстенә алды. Язылышу шәһәр загсында, ә туй мәҗлесе исә Гөлҗиһан яшәгән тулай торакның ашханәсендә булырга тиеш иде. Ябык шәһәр булганлыктан, авылдан, Миасстан Иртәшкә туган-тумачаны чакырып тормадылар, алар барысы да Караболакка, никах мәҗлесенә чакырылган иде. Иртәштәге туй мәҗлесенә, Гөлҗиһанның хезмәттәшләреннән тыш, биредә яшәүче бөтен Караболак татарларын чакырдылар. Иң кадерле кунаклары исә мәрхүм Хәбибулла абыйсының хатыны Таифә җиңги һәм Сөнкүлдән Җәүһәрия түти иделәр. Шулай ук Фәргатьнең бергә укый торган курсташ егетләре дә җыелды. Шулай итеп, кечкенә генә дип уйланган туй мәҗлесе ярты шәһәрне җыйды, ул көнне тулай торак бинасы биеп, җырлап, ду килеп торды.

Гөлҗиһан белән Фәргатькә сокланмыйча карау мөмкин түгел иде.

Алар икесе дә яшьләр, матурлар, горурлар, төз, зифа буйлылар. Икесе дә күз явын алырлык затлы итеп киенгәннәр, әйтерсең лә алар авылда туып үсмәгән, гомер буе хан сарайларында яшәгәннәр. Фәргатьнең дөм сукыр икәнлеген кайберәүләр хәтта аңламый да калдылар, чөнки Гөлҗиһан аны кысып култыклап алган һәм бүгенге көннән алар бер тән, бер җан булып хәрәкәт итәләр иде. Шушы көннән Гөлҗиһан Фәргатьнең күзләре дә, аяк-куллары да иде. Ул аның гомер юлын бергә үтәргә тиешле тормыш иптәше, законлы хатыны иде. Әмма Аллаһ каршында ул бары тик никахтан соң гына иренең хәләле була ала иде.

## Егерме дүртенче бүлек

Икенче көнне, больницадан биргән җиңел машинага төяләп, Караболакка кайтып киттеләр.

Алга, шофер янына, Таифәттәйне утырттылар, артта исә Гөлҗиһан белән Фәргать һәм Җәүһәрия түти урнаштылар. Дус-иш, таныш-белеш аларны больница бистәсе буйлап, кул болгап озата барды, бу гади татар кызының туе барысы өчен дә бәйрәмгә әйләнгән иде. Аның шушы кадәр гүзәллеге, булганлыгы белән сукыр егеткә кияүгә чыгуын күпләр вакыйга итеп кабул итте. Бу, чыннан да, әкияттәге могҗизага тиң иде. Моны күреп, каты авыруларда да өмет уянды, алар да үз тормышларында шундый изге җаннар очрасына ышанып яши башладылар. Тоташ авырулар арасында, атом казаны өстен-

дә утырган Иртәш халкына менә шундый яхшы үрнәк, җан-да өмет тудырырлык хәлләр, соклангыч парлар кирәк иде. Гөлҗиһан белән Фәргать шушы эчкерсез бәхетнең якты үрнәге, мисалы булып торалар иде.

Шулай итеп, җиргә беренче кар яуган ап-ак көнне Фәргать белән Гөлҗиһан Караболакка никах мәҗлесенә кайтып киттеләр...

Машина арты тулы бүләкләр, кучтәнәчләр, һәрберсенә өлеш бар. Аларны Гөлҗиһан Таифә һәм Җәүһәрия апалары белән берлектә ай буе җыйды. Башта Гөлҗиһан исеменнән Фәргатьнең әнисенә, әби-бабаларына, туганнарына бүләкләр алдылар, аннан Фәргать исеменнән Гөлҗиһанның әти-әнисенә, әби-бабаларына, Таһирҗан бабайга, башка туганнарына кияү бүләге җыйдылар. Күрше-күләннәр, чыбык очлары да калмады, һәрберсенә бер яулык, бер кием оектан булса да өлеш чыгарырга тырыштылар. Фәргать пенсиясенең бер өлешен кассага салып барган булган икән, туй чыгымнарына да, бүләк-санакка да ул бик ярап торды. Гөлҗиһанның да җыйгалап барган маясы бар иде, тигезләп бүлә торгач, барысына да җитте. Ә авылда исә аның сандык тулы бирнә малы, әнисе әзерләгән ястык-мендәрләре, үзе чиккән тастымал-сөлгеләре, тәрәзә пәрдәләре, чаршаулары бар иде. Бу бирнә малы, Караболак гадәте буенча, кыз бала тууга әзерләнә башлаган иде.

Ә классташы Рәшидәгә Гөлҗиһан алдан ук махсус бүләк алырга ниятләп куйган иде. Аның инде җәйге киемнәре күп икәнен ул белә, Гөлҗиһан аларны шактый алып кайтты, ә менә Рәшидәнең язгы-көзге киеме һаман шул бер иске бишмәт икән. Бер кайтканда аны шул киемнән күреп, Гөлҗиһан елап җибәрә язды, чөнки бу аның мәктәп елларыннан калган иске бишмәте иде. Һәм Гөлҗиһан Рәшидәгә өр-яңа плюш жакет алып кайтырга булды.

Ул вакытта авыл кызлары арасында иң модалы кием — елкылдап торган, кап-кара плюш жакет иде. Аны кигәч, Караболак кызларын танырлык та булмый, шәһәр артистларымыни?! Шуның өстеннән кечкенә яшел шәл дә ябып җибәрсәңме? Бетте, син авылның иң гүзәл кызы буласың инде. Әле аягыңда «прощай» дип аталган каптырмалы итекләр дә булса?! Чиләбе, Сверлау кебек зур шәһәрләргә барып урнашкан авыл кызлары Караболакка әнә шулай киенеп кайталар, киез итек һәм мамык шәлгә уранган авыл кызлары алар янында бәп-бәләкәй булып, бөтенләй кечерәеп кала. Һәм Гөлҗиһан, икешәр смена эшләп акча җыеп, классташ дустына да әнә шундый плюш жакет сатып алды. Ә яшел шәл белән «прощай»ны үзенекен бирергә булды, чөнки Гөлҗиһанның да гел яңаны алырга артык мөмкинлеге юк иде.

Иртәштән Караболакка ерак ара түгел, тиз кайтсаң, бер сәгатьтә дә кайтып җитеп була. Әмма алар бик ашыкмадылар, җайлап кына, шәһәрдән алган тәмле-томлыны, күчтәнәчләрне әйбәтләп саклап кына, дөньяга хозурланып кына кайтырга булдылар. Никах мәҗлесе әле кичке якта, ахшамнан соң гына билгеләнгән, шуңа күрә әкрен кайтсаң да өлгерергә була иде. Юллар инде тәмам катырган, өстән ап-ак кар да явып үткән. Юл буендагы каен урманын тоташы белән бәс сарып киткән, алар көндезге кояш нурында күз явын алырлык булып җемелдиләр. Дөнья шундый матур, шундый саф аклык, нәкъ Гөлҗиһанның төшләрендәге кебек тоташ нурдан тора. Гөлҗиһан Фәргатьнең куенына кереп бетеп утырган, ул аның йөрәк тибешен ишетә, тән җылысын, җан җылысын тоя. Әйтерсең лә ул Фәргать белән бергә Иртәш, Караболак өстеннән оча, бәхете каршына оча.

Кышкы көн тиз караңгылана, Караболакка килеп җиткәндә, инде эңгер-меңгер төшкән иде. Шулчак, барысын да таң калдырып, авыл өстенә сәер нур таралды, кышкы күктә аҗаган уйный башлады. Аллакүл тирәләреннән күтәрелгән бу нур Караболак өстен яктыртып бераз торды да Гөлҗиһаннар кайта торган юлга төште. Аның яктысында ак кар өстендә чәчелеп калган салам бөртекләренә хәтле санарга була иде.

— Күк капусы! — дип кычкырып җибәрде Гөлҗиһан, үзе дә сизмәстән. — Күк капусы ачылды, Фәргать, теләк телик!

— Минем теләкләрем тормышка ашты инде — син янымда, — диде Фәргать, аны күкрәгенә кысып.

— Минем дә, — диде Гөлҗиһан, башын аның күкрәгенә салып.

Әмма икесе дә эчтән генә балалар турында уйладылар.

Гөлҗиһан Фәргатькә, Фәргать Гөлҗиһанга үзеннән бала булмаячагы турында әйтмәде. Алар, могҗиза көткәндәй, әле һаман нәрсәгәдер өмет итәләр иде. Алар, гомумән, бер-берләренә авырулары турында бер нәрсә дә сөйләмәделәр. Мондый бәхетле мизгелләрендә берсенең дә чир-газапларын исенә төшерәсе килмәде... Инде табышкач, инде кавышкач, боларның берсе дә булмас, мәхәббәт каршында бу авырлыклар барысы да чигенерләр, юкка чыгарлар кебек тоелды аларга. Дөнья бит бу — сукыр күрә башлый, баласызлар бала бәхетенә ирешә, әҗәл чирлеләр аякка баса. Бу тормышта алар белән дә нәкъ шулай булыр кебек тоелды Гөлҗиһан белән Фәргатькә. Әмма мондый бәхеткә ирешү өчен бик күп сынаулар үтәргә, авырлыклар күрергә туры киләчәк иде әле аларга...

Караболак аларны шаулап-гөрләп, бәйрәмчә каршы ал-

ды. Әллә күк капусын карарга, әллә Гөлҗиһаннар кайтканын ишетеп, ярты авыл урамга чыккан иде. Яшь-җилкенчәк, бала-чага, авыл башына ук чыгып, гармуннар уйнатып, Гөлҗиһан белән Фәргатьне каршы алдылар. Кем җырлый, кем бии, кем Караболак гадәте буенча юлга кәнфит-прәннек чәчкәнне көтә. Таифәттәй белән Җәүһәрия түти, алдан әзерләнгән капчыклардан алып, юлга тәмле-томлы чәчә, вак акчалар сибеп җибәрә. Бала-чага, ак карны пыр туздырып, аларны җыя, чүпли башлый. Гөлҗиһан кечкенә чакта үзе дә күп җыйды кияү күчтәнәчен, иң күп акча да, кәнфит-прәннек тә аныкы була иде.

Шулчак Гөлҗиһан бер читтә нәүмиз булып басып торган Рәшидәне күрде. Ул да, балалар белән бергә, юлдан акча һәм кәнфит җыймакчы була, әмма әллә ояла, әллә башкалар ирек бирми, башын иеп, бер читтә басып тора. Өстендә һаман шул иске бишмәте. Аны күргәч, Гөлҗиһан атылып классташы янына йөгереп килде, аны мәктәп елларындагы кебек кысып кочаклап алды. Рәшидә, салкын борынын Гөлҗиһанның җилкәсенә төртеп, мышкылдый ук башлады:

— Миңа кияү күчтәнәче калмады, миңа кияү күчтәнәче калмады, — дип такмаклый иде ул балалар кебек.

— Синңамы? — дип сорады Гөлҗиһан, Рәшидәне машинага таба алып китеп. — Сиңа бүләкнең иң зуры, Рәшидә! Без сиңа менә нәрсә алып кайттык.

Һәм ул, бөтен халык алдында, Рәшидәгә елкылдап торган кара жакет чыгарып тоттырды. Моны күреп, бөтенесе аһ итте, Рәшидә хәтта ятсынып читкә тартылды. Әмма бүләк шулхәтле матур иде, Рәшидә барысын да онытып, ике кулын сузып, аңа үрелде, жакетны Гөлҗиһаннан алып, күкрәгенә кысты. Гөлҗиһан аңа төенчек белән тиз генә үзенең яшел шәлен һәм «прощаен»да бирде, иске бишмәт кесәләренә кәнфитпрәннеген тутырды. Рәшидә, бүләк-күчтәнәчләрне күкрәгенә кысып, авыл буйлап йөгерде, очраган һәрбер кешегә ул Гөлҗиһанның үзенә матур бишмәт алып кайтуын сөйләде, жакетын әйләндереп-әйләндереп күрсәтте. Аннан, туганнарына мактаныр өчен, өенә йөгерде.

Гармуннар уйнатып, кышкы юлга вак акчалар сибеп, Гөлҗиһаннар капка төбенә килеп туктадылар. Өйдән йөгерешеп ата-аналар, әби-бабайлар, туган-тумачалар чыкты, китте кочаклашулар, китте елашулар. Иң тетрәндергеч очрашу Фәргать белән әнисе арасында булды, биш ел буе күрешмәгән ана белән бала, бер мәлгә никах мәҗлесе турында да онытып, бер-берләренең күкрәкләренә капландылар. Яңадан җан иңдерергә теләгәндәй, ана баласының сукыр күзләреннән сыйпады, бала анасының хәсрәт салган тирән җыерчыкларын капшады. Ул арада игезәк кыз туганнар да абыйларына килеп

сарылдылар, бөтен урам, Караболак ярату һәм сагыну сүзләре белән тулды. Фәргатьнең бу бәхетен Гөлҗиһан читтән генә, шатлык яшьләре аралаш күзәтеп торды. Бу бәхетле очрашуда үзенең дә катнашы барлыгын уйлап сөенде ул.

Аларга никахны Таһирҗан бабай үзе укыды.

Гөлҗиһанга ап-ак яулык бәйләтеп, Фәргатькә кара бәрхет түбәтәй кидереп, түр башына менгереп утырттылар. Караболак гадәте буенча, ирләр өстәлнең бер ягына, хатын-кызлар икенче якка тезелешеп утырдылар. Өй эче тантаналы серле тынлык белән тулды. Ап-ак күлмәге өстеннән кара кәзәкиен киеп куйган Таһирҗан бабай үзе дә дулкынлана кебек, Коръән тоткан кулы калтырап-калтырап куя. Чөнки могҗизага тиң бу хәлләргә кеше ышанырлык түгел бит. Гөлҗиһанның бу бәхетендә ул үзенең дә бераз катнашы барлыгын белә, шуңа күрә аеруча бер җан рәхәтлеге кичерә. Ул Гөлҗиһанны үз баласы кебек яратты, үзендә булган бар гыйлемне, иман нурын аңа да биреп калдырасы килде. Ул аны үзенең дәвамчысы итеп күрде, әмма зур, катлаулы бу юлның Гөлҗиһан әле башында гына басып тора иде.

Таһирҗан карт башта бик моңлы тавыш, Караболак көе белән Коръән укыды. Бу шулхәтле тантаналы һәм җитди мизгел иде, Гөлҗиһан тирән итеп сулыш алырга да базмады. Фәргать тә Коръән моңын тын да алмыйча тыңлый иде. Бу мизгелләрдә алар әйтерсең лә, җитәкләшеп, күкләр каршында басып торалар иде. Әнә зәңгәр күктән, гаҗәеп моңлы тавыш белән берәү сорый:

— Син, Якуп улы Фәргать, Нәбиулла кызы Гөлҗиһанны үзеңә хәләл җефет итеп алырга ризамы?

Янәшәдә генә Фәргатьнең каушаудан бераз карлыккан тавышы ишетелә:

— Риза... Мең риза.

Күктән килгән тавыш инде Гөлҗиһанга мөрәҗәгать итә:

— Син, Нәбиулла кызы Гөлҗиһан, Якуп улы Фәргатькә хәләл җефет булып барырга ризамы?

Башы бик нык әйләнүдән Гөлҗиһан дәшә алмый, аның күз алдында табын һәм өй эче әйләнә башлый. Барысы да, тынып, Гөлҗиһанның җавабын көтә. Күктән килгән тавыш тагы кабатлый:

— Син, Нәбиулла кызы Гөлҗиһан, Якуп улы Фәргатькә хәләл җефет булып барырга ризамы?

Шулчак Гөлҗиһанның колагына Фәргатьнең авыр итеп ыңгырашып сулыш алганы ишетелә. Гөлҗиһанны чорнап алган ак томан артыннан сулкылдап, ул аннан җавап көтә. Шул тавышка сискәнеп, Гөлҗиһан күзләрен ача, каршында ап-ак булып агарган Фәргатьне һәм аптырап калган Таһир-

җан бабайны күрә. Әйе, бу бит аның никах мәҗлесе, аннан Фәргатькә кияүгә чыгарга ризалыгын сорыйлар. Әлбәттә, риза Гөлҗиһан, бу хакта сорап тормаса да була иде Таһирҗан бабасына!

— Риза, Таһирҗан бабай, риза, бу хакта үзең дә беләсең бит инде.

Аның җавабын ишеткәч, өйдәгеләр җиңел сулап, елмаешып куйдылар. Чөнки бу ут чаткысы Гөлҗиһаннан барысын да көтәргә була.

— Тәртибе шундый, кызым, сорарга кирәк, — диде Таһирҗан карт, җитди булырга тырышып.

Кияү белән кәләштән ризалык алганнан соң, Караболак гадәте буенча, шаһитлар үз сүзләрен әйттеләр, мәһәр турында килешенде. Шушы рәсми өлештән соң, Таһирҗан карт шаулатып дога кылды, яшьләрне Аллаһ каршында ир белән хатын дип игълан итте. Аннан инде котлаулар, бүләк-күчтәнәч өләшүләр, сәдака бирүләр китте. Инде мәҗлеснең бу өлеше дә тәмамлангач, өстәлгә берсе артыннан икенчесе сыйхөрмәт, ризык-нигъмәт чыга башлады. Башта, татар гадәте белән, шулпалы аш килде, өстәлнең төрле урыннарына таутау өеп, кайнар ит куелды. Аннан табынга итле бәлеш, аннан дөгеле бәлеш, җимешле бәлеш чыгып утырды. Кунаклар әдәп саклап, тыйнак бер тәртип белән, мактап, рәхмәтләр әйтеп, бар нигъмәттән дә авыз иттеләр. Иң соңыннан өстәлгә чәй килде, чәй янына өем-өем чәкчәк, табак-табак коймак-кабартма, балы-мае, вареньесы, шәһәр татлылары чыгып утырды. Ул арада ике яктан да сүз алып, яшьләргә матур-матур теләкләр дә әйтеп өлгерделәр. Караболакта чын мәгънәсендә никах туе бара иде. Фәргать белән Гөлҗиһанның никах мәҗлесе бара иде.

Гадәттә мондый мәҗлесләр чәйдән соң тәмамлана һәм бирedә дә шулай булды. Ашка дога кылгач, олы як, күчтәнәчләрне кыстырып, өйләренә таралыша башлады, яшьләр исә клубка җыендылар. Никах мәҗлесендә җыр-биюләр каралмаганга күрә, яшьләр монысын клубта дәвам итәргә булдылар һәм, шаулашып, кышкы урамга сибелделәр. Караболакның карлы урамнары аларны җиңелчә салкынлыгы, аклыгы һәм сафлыгы белән каршы алды. Әллә кайдан гармунчысы килеп чыкты һәм сыздырып уйнап та җибәрде. Караболак өстенә татар моңы агылды, ул кичке тәрәзәләрне һәм хисле күңелләрне чиртеп үтте, картларга яшьлекләрен искә төшерде, яшьләрне үз янына чакырды. Фәргать белән Гөлҗиһан, үзләрен чорнап алган авыл яшьләре уртасында, утлары келпеп торган клубка юнәлделәр. Аннан гармун тавышы, җыр-бию авазлары яңгырап тора иде. Караболакның

бөтен яшьләре, зурлап, Фәргать белән Гөлҗиһанның никах туйларын котларга чыкканнар иде. Хәтта олыраклар да түзмәгән, парлашып, бу вакыйганы карарга килгәннәр, Фәргать белән Гөлҗиһанны олы тормыш юлына озатырга чыкканнар иде.

Караболак мондый кичәләрне уздыра белә, аның үзенең язылмаган тәртибе, кануннары бар. Мондый вакытта җырлар яшь парларга багышлана, биюләр алар тирәсендә бара, иң матур сүзләр алар өчен әйтелә. Әнә бүген дә яшьләр түгәрәк ясап алганнар да, уртага Фәргать белән Гөлҗиһанны бастырып куеп, җырлый-җырлый әйләнәләр:

Караболак урамы,
Бу дөньяда сезнең кебек
Матур ярлар булмады.

Аннан Фәргать белән Гөлҗиһан уртада, кара-каршы басып, биергә тиешләр. Алар биегәндә, тагы махсус җыр җырлана:

Таш ташыйлар, ком ташыйлар
Чиләбе юлларына.
Аерып алулары авыр,
Бирмә ят кулларына.

Җыр-бию туктап торган арада, уртага чыгып котлашулар, матур теләкләр әйтү китә. Бу сүзләрдә, бу хәрәкәтләрдә ник бер тупаслык булсын, ник бер хөсет-начарлык чагылсын. Караболак яшьләре, аларның ата-аналары, әби-бабалары кебек, хәзергә әле чиста, эчкерсезләр. Авыл өстенә килгән зур афәт тә, һәрберсенә диярлек килеп кагылган каты авырулар, якыннарының үлеме дә биредәге яшәү рухын, тормыш дәртен әле сүндерә алмаганнар. Шуңа күрә алар кешеләргә бары тик яхшылык кына тели беләләр, яхшыга гына ышаналар. Шуңа күрә алар үзләрен басып бара торган кара тормыштан да яктылык табарга тырышалар, бәхетләренә ике куллап чытырдатып ябышалар.

Карурманда кар тирән,
Итәгеңә кар тигән.
Һәр китапны укып киләм,
Сөйгәнеңне ал, дигән.
Ай-ли, баланым,
Түгәрәгем, кызыл бит.
Җаның сөйгән, теләгәнең
Белән тигез гомер ит.

Яшьләр шулай җырлап бетермәделәр, клубка йөгереп Рәшидә килеп керде. Ул өр-яңа кара жакеттан, башында читчитләре укалы яшел шәл, аякларында каптырмалы «прощай»

иде. Аны күргәч, башта танымыйча тордылар, аннан Рәшидә икәнлеген белгәч аһ иттеләр, кул чабып уртага чакыра башладылар. Бүген Фәргать белән Гөлҗиһанның туе, бүген җаны теләгән һәр кеше түрдә була ала иде. Рәшидә башта оялып торса да, Гөлҗиһанның үзен чакыруын күргәч, тизрәк аның янына барып басты. Ул арада гармунчы өздереп бию көен уйнап җибәрде, яшьләр, түгәрәкләнеп, кул чабып тора башладылар. Гөлҗиһан Рәшидәне кулларыннан алып, клуб буйлап биеп китте. Рәшидә моңа балалар кебек куанды, кайда икәнлеген дә онытып, «прощай»ларын тыпырдатып, Гөлҗиһан белән бии башлады. Бүген дөньяда аннан да бәхетле кеше юк иде, бу клубта аннан да матур кыз юк иде. Ул моңа чын күңеленнән ышана, чөнки аның матур шәле һәм итеге, бәрхет бишмәте бар иде! Аңа бәхетле булу өчен хәзер шушылар да җитә иде.

Рәшидә арганчы биеде. Аннан, Караболак гадәте белән, тып итеп кияү егет каршына килеп басты, берни аңламый торган Фәргатьнең кулларыннан алды да, аның белән бии-бии, Гөлҗиһан янына килде. Хәзер Гөлҗиһан белән Фәргать бергә биергә тиешләр иде, Рәшидә нәкъ шуны тели иде. Моны күреп, башкалар да кул чаба башлады. Бичара Рәшидә хакына, авылдашлары өчен, Фәргать белән Гөлҗиһан клуб уртасында салмак кына парлап бии башладылар. Аларга сокланмыйча карау мөмкин түгел иде. Очарга торган аккош кебек горур һәм гүзәл Гөлҗиһан. Аның янәшәсендә Урал таулары кебек мәгърур сынлы баһадир Фәргать. Караболакның иң матур, иң затлы балалары. Алар гүя биемиләр, ә Караболак өстеннән очып, йөзеп баралар. Милләтнең бик бәхетле һәм бик бәхетсез ике баласы. Алар хәтер күзәнәкләрендә меңьеллык нәсел тамгасын — татар тамгасын йөртәләр. Аларның бәгырьләренә атом тамгасы — үлем тамгасы да сугылган инде. Алар — милләтнең бөек үткәне белән фаҗигале киләчәген тоташтырып торучы соңгы буын. Алар язмышлары буйлап оча, ә аста дөнья белән бәхилләшеп яткан Караболак кала, әҗәл җиле кагылган кырлар кала, аларның язмышына әйләнәчәк Иртәш кала, үлем коралы ясап ята торган заводлар кала.

Канатлары көймәсен иде аларның бу атом утында, рухлары сынмасын иде, чөнки алар бу дөньяга бәхет өчен туган адәм балалары бит. Татар балалары...

Хәерле юл телик аларга.

*Беренче китап тәмам.*

ИКЕНЧЕ КИТАП

## Беренче бүлек

Алар Иртәш шәһәрендә яшәп калдылар.

Әлбәттә, Сөнкүлдә калырга да була иде, чөнки Җәүһәрия апалары аларны яшәргә үзләренә чакырды, әмма яшьләр хәзергә Иртәшне сайладылар. Чөнки Фәргатьнең укуы, Гөлҗиһанның эше шунда иде. Алга таба, бәлки, башка урынга күчәрләр, хәзергә аякка басканчы Иртәштә яшәргә булдылар. Иртәш — зур шәһәр, яхшы хастаханәләре, көчле югары уку йортлары бар, ә Фәргать белән Гөлҗиһанга хәзергә нәкъ шулар кирәк. Әмма Фәргатьне Сөнкүлдән җибәрмәс өчен Берия лабораториясе шактый тырышты, чөнки ул биредә тәҗрибә төркеменә керә һәм даими күзәтелә иде. Әмма Фәргатьнең Иртәштә каласын белгәч, алар килеште, аның бөтен анализларын Иртәш ФИБына җибәрделәр.

Фәргатьне бөтенләй Иртәшкә күчерү өчен, махсус рөхсәт алып, Гөлҗиһан Сөнкүлгә үзе керде. Ул яшәгән гарипләр йортын күреп, аның йөрәге өзелеп төшә язды. Шулхәтле фәкыйрьлек һәм шыксызлык, бөтен йортка, өс-башларга сеңгән авыр ис, күзгә кереп торган гарип-гораба, тиле-диваналар. Аның газиз Фәргате монда ничек яшәде икән? Шушылар арасында яшәп тә, ничек шулай асыл зат булып кала алды икән? Бәлки, бу хәлләрне күрмәве, дөм сукыр булуы аңа ярдәм иткәндер, тормыштан гайрәтен чигермәгәндер? Гөлҗиһан Фәргатьне тизрәк шушы бәхетсезләр арасыннан тартып алуына сөенде, язмышына рәхмәт әйтте.

Хәзер инде Иртәштә тору урыны эзләү кала иде.

Гөлҗиһан Фәргатьне больница бистәсендәге кызлар тулай торагына алып кайта алмый иде. Чөнки аның әле биредә эшли башлаганына бер ел да юк, ничек әрсезләнеп аерым бүлмә сорап йөрергә мөмкин? Кешеләр монда еллар буе гаиләләре, балалары белән бүлмәгә чират торалар бит. Аннан Гөлҗиһан Фәргатьне бу ыгы-зыгы арасына алып киләсе дә килми, ул аның белән тормышын аерым куыштан башлыйсы килә. Ә каян табасың Иртәштән аерым куыш?

Әти-әниләре, туганнары белән киңәшләшкәннән соң, ул Таифә җиңгәләренә барып карарга булды. Караболакка никах мәҗлесенә кайткач, ул үзе дә шундыйрак сүз ычкындырган иде, фатир таба алмасагыз, бездә яшәп торырсыз, дигән иде. Таифә җиңги Иртәш читендәге агач өйдә хәзер берьялгызы яшәп ята, кызлары Чиләбедә укып йөри. Курчак өе кебек бу йортны Хәбибулла әзи үзе исән чакта ук төзегән булган, әмма анда яшәп кенә өлгермәгән. Гөлҗиһан, Иртәшкә килүгә, Таифә җиңгәсен эзләп тапкан иде, хәзер дә менә киңәшкә аңа бара.

Ак кар көртенә батып утырган бу агач йортка Гөлҗиһан үз өенә килгәндәй килеп керде. Агач өй, Караболак гадәте буенча, ике яклы итеп салынган, тыштан кечкенә кебек күренсә дә, эчтән шактый зур, иркен иде. Бөтен хуҗалык тормышы кече якта — зур миче, аш урыны, эш урыны, кыш өчен юынгычы. Ә олы як — кунаклар кабул итә торган урын, ак як дип атала. Караболакта Гөлҗиһаннарның үз өйләре дә шундый, картнәйләре, Таһирҗан бабайлары да нәкъ шундый өйдә тора. Хәбибулла абыйсы да өйне Караболактагы кебек салган булган, тик анда яшәргә генә насыйп булмады аңа.

Биредәге һәр әйбер Гөлҗиһанга Караболакны исенә төшерә иде.

Әнә түрдә зур агач кисмәкләрдә биек роза гөлләре үсеп утыра, бөтен тәрәзә төпләре дә шау чәчәкле гөлләр белән тулы. Гөлҗиһанның иң яраткан яран гөле, кына гөле, тамчы гөл. Тәрәзәләрдә — ак ефәк челтәрләр, шау чәчәкле пәрдәләр, тәрәзә араларында — чиккән сөлгеләр. Уң кул ягтарак — ак түгәрәк мич, аннан бөтен өйгә җылы бәреп тора. Мичнең бер өлеше һәм аның янындагы биек тимер карават та чәчәкле чаршау белән бүлеп алынган. Карават өстенә тау кебек кабарып торган мендәрләр өеп куелган, мендәр тышларында чиккән кызыл чәчәкләр. Бөтен өй эчен чиккән җете чәчәкләр белән тутыруның да үз сәбәбе бар — бу татарларның матурлыкка омтылуыннан килә. Урал артларында алты ай салкын кыш, ак кар, өч ай язгы-көзге пычрак, чәчәкле җәйгә нибары өч ай вакыт кала. Чәчәкле җәйне сагыну хисе менә шулай итеп чигүләргә күчә, озын салкын кышларда җанны җылыта, күзне иркәли.

Өйдә чаршаулар да күп — ишектә дә, аралык араларында да, карават алларында да. Аларда бер йорт эчендә ишле гаилә булып яшәгән татарның үзенә генә хас тәртибе, әдәбе-әхлагы чагыла. Чәчәкле чаршаулар — татар халкының тормыш өчен менә дигән җайланмасы. Өйгә ямь дә биреп тора, шул ук вакытта тиешсезен ят күзләр дә күрми, теләсәң — ачып, кирәк вакытта ябып куясың.

Боларны күргәч, Гөлҗиһан тагы бер тапкыр соклануын белдерде:

— Нәкъ безнең Караболактагы кебек, Таифә җиңги! — диде ул. — Сезгә килгәч, үз өемә кайткан кебек булам кый.

— Хәбибулла абыең нәкъ шулай булуын теләгән иде шул, сеңелем, — диде Таифә җиңгәсе. — Һәр бүрәнәсен, һәр тактасын берәмтекләп җыеп, күгәрчен өе кебек итеп салган иде йортыбызны. Биредә яшәргә генә насыйп булмады үзенә. Әзмәвер кебек кеше күз алдында тәгәрәде дә үлеп китте. Үлгәненә дә ун ел инде менә.

Ун ел...

Бура кебек Хәбибулла абыйсының кибеп-корып, Караболакка кайтып егылганын хәтерли Гөлҗиһан. Ул вакытта кыз үзе дә яшәү белән үлем арасында кан косып ята иде. Хәбибулла абыйсы үлгәндә ул әле аңына килә генә башлаган иде. Аннан, ни хикмәт, терелеп китте. Ә Нурҗамал әбисе, кече улы үлгәч, бераз җиңеләеп, саташып йөргән иде. Аның улы турындагы бәетен әле дә хәтерли Гөлҗиһан, аны бөтен өй белән елый-елый тыңлаганнар иде. Кем уйлаган, ун елдан соң Гөлҗиһан атом шәһәрендә абыйсы салган йортка килеп керер дип.

Тугыз ай күтәреп йөрдем,
Тугач та сөтемне бирдем.
Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран,
Баламның хәсрәтен күрдем.

Бала дигән асыл агач
Ананың карынында ята.
Баланың канлы хәсрәте
Ананың йөзен саргайта.

Шушы бәетне искә төшереп, алар Таифә җиңгәсе белән елашып та алдылар.

— Мин үзем Караболакныкы түгел бит, сеңелем, күрше авылдан, — дип дәвам итте Таифә җиңгәсе. — Әмма сезнең авылны бик якын итәм, Хәбибулла абыең хакына, аның рухы шат булсын дип, барыгызга да иң якын туганнарым итеп карыйм. Ошатсаң, менә бездә торырсың Фәргать белән. Фәргатьне бик якын иттем, сеңелем, кайсыдыр ягы белән Хәбибулла абыеңа охшаган ул, балакаем. Бер авылдан бит, бер Караболак суын эчеп үскән күрше егетләре. И, язмыш, шушында килеп, башларына чир тапсыннар инде. Безнеке кебек әҗәл чире генә була күрмәсен инде, сеңелем, бик яхшы кара. Үзең табиб кеше булгач, ничек тә сакларга тырыш Фәргатьне.

Фәргатьнең сукырлыгы турында туганнар белән бик ачылып сөйләшмәсәләр дә, Гөлҗиһан аның нурланыш белән авыруын, I группа инвалид булуын белә иде инде. Гөлҗиһан нурланышның да нәрсә икәнлеген яхшы белә хәзер, ул — күзәнәкләреңә радиация үтеп кереп, эчтән җимерә, черетә, үтерә башлау дигән сүз. Берәүләр моңа бик тиз бирешә, берәүләр шактый озак тартыша әле. Гөлҗиһан мондый авырулар белән хәзер Иртәш больницасында көн саен, сәгать саен очраша. Ул шуңа да игътибар итте — бу авырудан тиз генә үлеп китүең яки яшәп калуың нинди тормыш алып баруыңа, ничек туклануыңа да бик нык бәйле иде. Шуңа күрә Гөлҗиһан, Фәргатькә бик сиздермичә генә, аны үзе белгән алымнар белән дәвалап карарга булды.

Шулай итеп алар Иртәштә, Таифәттәйләрдә яшәп киттеләр.

Шәһәр читендәге бу агач өй аларга оҗмах булып тоелды.

Гөлҗиһан үзенең сөйгән яры белән, хәләл пары белән нәкъ менә шундый өйдә яшәргә тиеш иде.

Гөлҗиһан — эшен, Фәргать укуын дәвам итте, бәйрәм саен төялеп Караболакка кайттылар, Миасска бардылар, җәй чыкканда, санаторий, ял йортларын да калдырмадылар. Бу елларда Гөлҗиһан бары тик Фәргать өчен генә яшәде, аның авыруларын, гадәтләрен яхшылап өйрәнде, иренең хәлен җиңеләйтү өчен елан сөте табарга да риза иде ул. Ул аның да, үзенең дә барлык газаплары, авырулары радиациядән икәнлеген белә иде инде, шуңа күрә организмнан шуны чыгару өчен дөньяда нәрсә бар, шуларны эзли башлады. Аллакүл чишмәсе суы да, зәңгәр балчык та, халык телендә алтын тамыр дип аталган тау үсемлеге дә калмады. Карабодайны һәр иртәдә кефирда әчетеп ашату дисеңме, чи чөгендер, чи кишер, чи бәрәңге кырып бирү дисеңме — барысын да эшләп карады Гөлҗиһан. Больницага килгән бөтен яхшы даруларны ул Фәргатькә эчереп барды, аны больницаларга салып, канын юдырды, химия эшләтеп карады. Гөлҗиһан күрде — Фәргать сыкранып, сызланып йөрмәсә дә, аның анализлары әле һаман әйбәт түгел иде. Ул шуны да аңлады — биредә, Иртәштә яшәп, алар радиация алуларын дәвам итәләр иде.

Әмма бу тирәдә кая гына барсаң да шушы хәл, кая барсаң да радиация, нурланыш. Караболакта да, Коншакта да, хәтта Чиләбедә дә. Биредә нурланыш авыруына каршы көрәшә торган махсус больницалар бар. Табиблар, медицина бик көчле, Мәскәүдән, хәтта чит илләрдән яңадан-яңа дарулар кайтып тора. Башка җирдә боларны таба алырлармы соң алар? Чиләбедә аларны кем көтеп тора? Һәм алар, Фәргатьнең укуы беткәнче, Иртәштә торып торырга булдылар, табиблар да шулай киңәш итте. Мондый авыру белән урын һәм климат алыштыру бик зарарлы икән, организм инде шушы һавага, шушы суга ияләнгән, башка шартларда ул көрәш сәләтен югалтырга мөмкин икән.

Әмма Гөлҗиһан белән Фәргатьне эчтән генә иң кимергән һәм кимсендергән нәрсә авыру түгел, аларның балалары булмавы иде. Бер караганда, мондый сәламәтлек, мондый диагноз белән бала табарга да куркыныч, аның тере гарип булып тууы бар. Икенче яктан, баласыз тормыш нәрсә инде ул? Аларның икесенең дә нәселләрендә унар бала булган, ә алар берлексез. Бу баласызлыкта һәркем эчтән генә үзен гаепле итеп сизде, чөнки икесе дә үз хәлен, үз авыруын белә иде. Әмма бу хакта ачылып сөйләшергә уңайсызландылар, «шулай язгандыр инде» дип, бу хәлләре белән эчтән генә килеш-

теләр. Чиләбедә гарип балалар йортында булып кайтканнан соң, Гөлҗиһан бу турыда уйларга да курка башлады, анда күргәннәр Гөлҗиһанны тәмам аяктан еккан иде.

Гөлҗиһан эшләгән больницада да гарип балалар еш туып тора һәм ата-аналары алмаса, аларны Чиләбегә озаталар иде. Кешегә күрсәтергә куркыныч гарипләрне исә ата-аналарына әйтеп тә тормыйлар, «балаң үле туды» диләр дә, аерым бүлмәгә бикләп куялар. Гөлҗиһан монда бер күзле, ике авызлы балаларны да, балык койрыклы гарипләрне дә, ике башлы мутантларны да күрде. Әмма Чиләбедә күргәннәре моннан да куркынычрак, коточкыч булып чыкты.

Берничә шушындый гарип бала җыелгач, аларны, медсестралар белән бергә, Чиләбегә озаталар иде. Бер тапкыр шулай Гөлҗиһанга да барырга туры килде. Аннан кайткач, ул атна буе ашый алмады, гел укшып йөрде, кулыннан эш төште, Фәргать янына ятырга курка башлады. Чөнки ул Чиләбедә кыямәт көненең үзен, заман ахырын күреп кайткан иде.

Шәһәр читенә, урман эченә урнашкан бу балалар йортын, йомшартып, интернат дип йөртсәләр дә, ул тере гарипләр, куркыныч гарипләр больницасы булып чыкты. Биредә бер яшьтән унсигезгә хәтле балалар яши икән, әмма аларның бик сирәкләре генә бу яшькә җитә, калганнары үлеп бара. Больницага килеп керүгә, бугазга ачы ис ябыша, тын алып булмый, күзгә яшь бәреп чыга. Гөлҗиһан Иртәштән алып килгән балаларны бер бүлмәгә алып керде һәм мондагы хәлне күреп, аларны кулыннан төшереп җибәрә язды. Зур бүлмәдә егерме-утыз бала ята. Аларны гарип дип кенә әйтү аз, алар — карарга куркыныч ит кисәкләре. Араларында инде унике-унөч яшькә җиткәннәре дә бар, әмма аларның гәүдәләре терсәк буе гына, кул-аяк урынына — тырпаеп торган ит тумраннары. Ә аларның йөзләре исә җитмеш яшьлек картларны хәтерләтә, азау тешләре саргаеп, авыз кырыеннан асылынып төшкән. Алар барысы да сабый балалар өчен ясалган караватларда яталар, идәнгә төшерсәң, кортлар кебек шуыша башлыйлар. Араларында башлары күкрәктән үсеп чыкканнары, аяк урынына — кул, кул урынына аяк үскәннәре дә бар. Аларның кайсы мөгри, кайсы эт кебек чиный, кайсы, тын гына шыңшып, үлем көтеп ята. Болар барысы да Иртәштәге атом комбинаты белән бәйле радиация корбаннары иде. Болар барысы да Иртәш тирәсендәге авыллардан һәм шәһәрләрдән китерелгән иде. Алар арасында татар балалары да күп иде.

Бу күргәннәреннән Гөлҗиһан Иртәшкә кадәр аңына килә алмады, берничә тапкыр машинаны туктатып, битен кар белән юды. Ул дөньяның азагын күргән кебек булды. Һәм бу дөнья җирдә шуышучылар белән бетәчәк иде.

Иртәшкә кайткач, ул озак вакыт шушы күргәннәреннән арына алмыйча йөрде. Үзенә, нәселенә шундый бәла килүдән коты чыкты.

Беренче тапкыр баласы булмауга сөенде. Ул тормышын ничек бар, шулай дәвам итәргә булды. Чиләбедә күргәннәре турында Фәргатькә берни дә сөйләмәде.

Шулай баласыз бер ел үтте, ике ел, өч, дүрт ел...

Ул арада Фәргать, укуын тәмамлап, судта адвокат булып эшли башлады. Гөлҗиһанны исә, гаять тырышлыгын, гаделлеген, кешелеклелеген искә алып, больницаның өлкән шәфкать туташы итеп билгеләделәр. Бу — бик күп вакыт сорый торган гаять җаваплы хезмәт иде, һәм Гөлҗиһан башы-аягы белән эшкә чумды. Үз эшендә Гөлҗиһан судагы балык кебек йөзде, бу өлкәдә ул белмәгән, ул эшли алмаган нәрсә юк иде. Үзе кебек үк авыруларның ул бер елга, бер айга, хәтта бер елга булса да гомерләрен озайту өчен бөтен көчен куйды, аларны дару белән генә түгел, шифалы карашы, җылы сүзе белән дә дәвалады. Больницада мондый кадерле белгечне югалтасылары килмәде, шәһәр исполкомы белән киңәшеп, Фәргать белән Гөлҗиһанга тизрәк бер бүлмәле яңа фатир биреп куйдылар. Шулай итеп, алар Иртәшкә тәмам тамыр җибәрделәр, шәһәрнең билгеле, хөрмәткә лаек кешеләренә әйләнделәр. Бәлки, шулай тыныч кына яшәп тә бетергән булырлар иде, әмма язмыш әле аларга үзенең бик күп сынауларын әзерләп куйган булып чыкты.

Һәм бу хәлләр игезәкләр тугач башланды.

## Икенче бүлек

Гөлҗиһан әле дә хәтерли — ул елны җәй гаять коры килде.

Җәй башында ук бөтен үләннәр корыды, агач яфраклары үсеп китә алмый саргайды, коела башлады. Картларның әйтүләренчә, Уралтау аръягында сугыштан соң шундый корылык булган, бөтен тирә-як кипкән-саргайган, игеннәр тамырыннан көйгән. Халыкның бер өлеше шул вакытта ачлыктан кырылган, шешенеп үлгән, хәллерәк кешеләр элеккеге барлык белән яшәп калганнар. Дөрес, Караболак ул хәтле үк бетеренмәгән, анда халык элек-электән яхшы яшәгән, әмма тирә-юнь авылларда ачлыктан күп үлгәннәр.

Быелгы җәйне дә шуңа охшаталар. Моның шулай икәнлегенә Гөлҗиһан авылга җиткәндә үк ышанды — кырлар кара янган, болыннар саргайган, тагы бераз шулай торса, бөтенесе дә бетәчәк иде. Хәзер июнь уртасы, майдан бирле бер бөртек яңгыр төшмәгән. Болай булса, бәрәңге дә бетәчәк, яшел-

чә-җимешләр дә тамырында яначак. Караболак елгасының да суы төбенә сеңгән, яр буйлары ачылып, аксыл ләм пар чыгарып ята. Тәрәзә каршындагы гөлләргә хәтле көеп, шәлперәеп төшкән. Авыл өстендә тузан, көек исе эленеп тора, әйтерсең лә әле генә зур янгын булган һәм аның исе таралып та өлгермәгән.

Хәтта сукыр Фәргать тә бу хәлне сизде, кипкән чәчәкләрне кулында уып, Караболакка әллә нәрсә булган, дип әйтеп куйды. Яңа гына Янгантау санаториесенда ял итеп кайтып, атна-ун көн вакытларын алар Караболак өчен калдырганнар иде. Һәр җәйне карттайлары йортында алар өчен ак якны калдыралар, Фәргать белән Гөлҗиһан, яшь чакларын исләренә төшереп, шунда ял итеп, ике йортка да булышып китәләр. Гөлҗиһан кайткан саен авыл халкына кирәк-ярагын, даруын алып кайта, кайсын Чиләбегә, кайсын Коншак больницасына салырга ярдәм итә. Ул аларны үзе эшли торган Иртәш больницасына да бик салып дәвалар иде, әмма Караболак халкын ябык шәһәргә кертмиләр, Гөлҗиһан шунда яшәгән авылдашларына гына ярдәм итә ала. Һәм шунысына да куанып бетә алмый.

Быел исә авыл халкы аларны бик борчылып каршы алды — Караболакта җир көя иде. Бөтен карап торганы җирдән булган халык өчен бу инде зур кайгы, зур югалту. Шуңа күрә картлар җыелып, үзара киңәшәләр, яшьләр аларның соңгы сүзен көтә.

— Дөнья корый, балалар, нәрсәдер эшләмичә булмый кый, — диде Таһирҗан карт, авылдагы иң өлкән кеше буларак. — Бүген җомга намазыннан соң кырга чыгып, яңгыр теләмичә булмый.

Гөлҗиһан кечкенә вакытта да шулай картлар кырга чыгып, яңгыр намазы укыйлар иде. Гөлҗиһан әле һаман да апак сакаллы бабайларның, җәймә җәеп, Аллакүл ягына карап намаз укуларын хәтерли. Авылның коммунист-комсомоллары аларны күрмәмешкә салыналар иде, чөнки яңгыр барысына да кирәк бит. Һәм, ни хикмәт, картлар намаз укып бетерү белән, коеп яңгыр явып үтә иде.

— Картлар инде бер-ике тапкыр чыгып карадылар, сибәләп кенә үтте, — диде Нурҗамал карчык, юлдан кайткан яшьләрне табын түренә утыртып. — Бөтен авыл белән чыгарга кирәк шул аны, яңгыр барысына да кирәк бит. Сез дә юлдан соң мунча кереп, госел коенып чыгыгыз, балалар, халык белән барырсыз. Кешедән калмагыз, картлар артына басып намаз укырсыз.

Ул арада җомга намазы бетте һәм халык төркем-төркем булып кыр ягына таба агыла башлады. Фәргать белән Гөлҗиһан да, юынып, чистарынып алып, яңа өс-башларын киеп,

аларга кушылдылар. Кешеләр сабантуйга киенгән кебек чиста һәм матур итеп киенгәннәр, әмма бәйрәмгә бармаганнарын яхшы аңлыйлар, шуңа күрә йөзләре җитди, телләрендә дога һәм теләк. Менә берзаман алдан барган картлар тәкбир әйтә башладылар, аны арттан баручылар, бөтен авыл халкы күтәреп алды. Караболак өстендә, Аллакүл буйларында җан тетрәтеп, меңьеллык таныш моң, мәңгелек таныш сүзләр яңгырый башлады: «Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр! Ләә иләһә иллалаһу, Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр!»

Тәкбир тавышы Караболакның һәр өенә, анда яшәүче һәр кешенең җанына үтеп керә. Ул аларны кубарылып кырга чыгарга, намазга басарга чакыра. Бу тавыш олысын-кечесен, баласын-чагасын бөтен тыкрыклардан, урамнардан кырга җыя, бер җиргә туплый, дөньяда Аллаһ барлыкны искә төшерә. Менә алар, кыйблага карап, кайнар туфракка тезелеп басалар. Гөлҗиһан белән Фәргать тә шулар арасында. Кайдандыр яннарына Рәшидә дә йөгереп килеп баса, аның өстендә Гөлҗиһан бүген генә алып кайткан яңа күлмәк, яңа яулык. Иң алда — Хозыр Ильяс кебек ак сакаллы, нурлы йөзле Таһирҗан карт басып тора. Ул бүген бөтен кавеме алдында имамлык итәчәк.

Таһирҗан картның моңлы авазы көеп яткан Караболак кырлары буйлап тарала, Урал тауларына барып җитә, зәңгәр күккә менеп китә. Әмма әле күк йөзе чалт аяз, анда ник бер генә болыт кисәге булсын. Таһирҗан карт артыннан кешеләр башларын җиргә оралар, сәҗдәгә китеп, Аллаһтан яңгыр сорыйлар. Аннан тагы бөтен авыл белән аякка басалар, аягүрә хәлдә, Аллаһтан яңгыр сорыйлар. Аннан тагы бөтен Караболак сәҗдәгә егыла, тагы тора, тагы сорый. Ак сакаллы картлар, кулларын күккә сузып, елый-елый дога кылалар, аларга кушылып, хатын-кызлар, балалар елый. Күзлесе дә, күзсезе дә елый, иманлысы да, имансызы да сорый, ышанганы да, ышанмаганы да тели. Чөнки барысына да яшәү кирәк, яңгыр кирәк. Аллаһ ярдәменнән башка алар үзләре күктән бер яңгыр тамчысы да яудыра алмыйлар иде.

Сәҗдәдәге халык баш күтәреп өлгермәде, Уралтау буйларын яңгыратып, күк күкрәгән тавыш ишетелде. Бу тавыш шулхәтле көчле иде ки, хәтта аяк астында җир селкенеп куйгандай булды. Аннан Аллакүл ягыннан салкынча җил исәргә тотынды, Караболак өстенә әллә кайдан гына кабарып торган болытлар җыела башлады. Җил көчәйгәннән-көчәя барды, ул инде давылга әйләнеп, халыкны кырдан куарга тотынды. Моны күреп, хатын-кыз авыл ягына йөгерде, аларга куркынган балалар иярде, ир-атлар, картлар исә, гаҗәпкә калып, табигатьтәге бу үзгәрешләрне күзәттеләр. Ул арада кабарынган болытлар арасыннан чәчрәп чыгып, җиргә чи-

ләкләп яңгыр коя башлады. Кешеләрнең кайберләре авылга йөгерде, кайберләре быелтыргы салам эскертләренә барып посты, кайберәүләр якындагы урманнарга кереп качтылар. Гөлҗиһан белән Фәргать, җитәкләшеп, якында гына күренеп торган Аллакүл ягына йөгерде. Гөлҗиһан яңгырны андагы тау куышында качып уздырырга булды.

Алар, юп-юеш булып чыланып, атылышып, тау куышына килеп керделәр.

Тау куышында, чыннан да, ышык һәм коры иде. Моннан тышта котырып яңгыр яуганы да күренми, җил-давыл улаганы да ишетелми, бөтенләй башка дөнья. Каяндыр еректан, җирнең төбеннән, челтерәп чишмә агып чыкканы ишетелә. Ул, кыя-ташларга сыенып, аларның астыннан диярлек агып бара да, куыш авызына җитәрәк, атылып өскә чыга һәм күлгә килеп коя. Тау куышы мәңгелектән бирле менә шушы чишмә җыры һәм ташлар моңы белән генә яшәп ята. Кешеләр хәзер бирегә бик сирәк киләләр шул.

— Бу нинди җир? — дип сорап куйды Фәргать, үзенең гайре табигый урынга килүен сизенеп.

Чөнки коеп яуган яңгыр да кинәт кенә әллә кая юкка чыкты, җил-давыл да ишетелми башлады, тирә-якта кешеләр дә юк, ахрысы...

— Аллакүл мәгарәсе бу, Биташ куышы, — диде Гөлҗиһан.

Фәргать нидер искә төшерергә тырышты. Ул әле кечкенә вакытта, алар әле Караболакта торганда, картнәе белән монда суга килгәне бар иде Фәргатьнең. Миасска куылгач та, әбисе гел шул суны, гел шушы тау куышын исенә төшерде, сагынып тилмерде. Менә кая алып килгән икән аны Гөлҗиһан, күрше кызы...

— Мин бәләкәй вакытта бирегә еш була идем, — диде Фәргать, караңгыда таныш эзләрне капшап табарга тырышкандай. — Монда әле чишмә дә бар бит. Әйе шул, һаман исән икән, әнә ничек челтерәп ага.

Алар, бер-берләренә сыенып, шактый вакыт чишмә тавышын тыңлап утырдылар. Таштан ташка сикереп аккан чишмә туктаусыз гөрләп тора иде. Аннан алар тау чишмәсенең суы белән бит-кулларын юдылар, кушучлап эчтеләр, балачага кебек, су сибешеп уйнадылар. Гөлҗиһан, куыш авызына йөгереп барып, урамга карап килде, анда яңгыр әле туктамаган, әмма инде бераз тынычланган, басылып кына ява иде. Зәңгәр күктә инде яңадан ялт итеп кояш та чыккан, Караболак өстенә кояшлы яңгыр ява иде. Ерактарак һаман эссе рәшә уйнап тора, анда яңгырның тамчысы да төшмәгән, ахры.

— Алланың хикмәте инде бу, — диде Гөлҗиһан, ире янына тау куышына кереп. — Безнең Караболак турында гына яуган бит бу яңгыр! Арырак анда рәшә уйнап тора...

— Халыкның намазы ярдәм иткән инде, — диде Фәргать уйчан гына.

— Гаҗәп инде. Әле генә үлеп, кибеп яткан коры җир иде бу тирәләр, яшәүнең әсәре дә калмаган иде. Хәзер күрсәң! Бөтен җир күзгә күренеп күтәрелә, сулыш алып ята, хәтта яшәреп килә! Менә бит Алланың хикмәте.

Фәргатьнең Гөлҗиһанга әйтер бик мөһим сүзе бар иде, әмма ул аны күпме вакыт әйтә алмый йөри. Өйләнгәндә, үзенең баласы була алмаячагы турында әйтмәде ул Гөлҗиһанга. Һәм менә ничә ел инде аларның балалары юк. Монда Фәргать үзен гаепле саный һәм бу хәлдән бик газаплана. «Гөлҗиһан башка кешегә чыкса, инде итәк тулы балалары булыр иде», — дип уйлый. Алга таба инде бу күңелсез серне яшереп булмый, уртага салып киңәшергә кирәк — йә ятимнәр йортыннан берәр бала алып карарлар, яки... Анысын Фәргать үзе дә белми, анысын инде Гөлҗиһан хәл итәчәк.

— Бер сәҗдә белән кипкән җирне яшәрткәнне, сорасаң, адәм баласына да ярдәм итә аладыр ул Аллаһ, — диде Фәргать, тагы үзенекен уйлап.

Гөлҗиһан инде шактыйдан ирен нидер борчуын сизенеп йөри иде. Ул төннәрен озак кына йокыга китә алмый, тирән итеп көрсенә, торып йөреп килә. Гөлҗиһан бу хәлләрне аның авыруыннан дип уйлый иде, ахры, иренең тәне түгел, җаны авырта. Нидер әйтәсе килә аның Гөлҗиһанга, тик әйтә алмый. Ул аңа үзе ярдәм итеп карарга булды.

— Әйтәсе берәр җитди сүзең бар, ахры, Фәргать, — диде ул, аның янына килеп утырып.

— Шушылай бик ялварып сорасак, Аллаһ безгә дә бала бирмәс идеме икән, Гөлҗиһан? Гомер үтеп бара бит.

Фәргатьнең бу сүзеннән Гөлҗиһан куырылып куйды. Ул бит кияүгә чыкканда Фәргатькә үзенең бала таба алмаячагы турында әйтмәде. Теле әйләнмәде, гел нәрсәгәдер өмет итте. Һәм менә аңар җавап тотар вакыт җитте.

Ул иренең җилкәсенә башын салды да үксеп елап җибәрде. Бу хәлдән Фәргатьнең коты чыкты, ул, берни аңламыйча, Гөлҗиһанны юатырга, тынычландырырга тырышты.

— Мин бала таба алмыйм бит, Фәргать, — дип үксеп дәвам итте Гөлҗиһан. — Зинһар, кичер мине, кияүгә чыкканда, бу хакта әйтә алмадым сиңа. Гел нәрсәгәдер өмет иттем, бәлки, булыр, дидем, төрле дарулар эчеп карадым.

— Син нәрсә сөйлисең, Гөлҗиһан?! — диде Фәргать, аны аңламыйча. — Мин сиңа дөресен әйтмәдем ул. Миннән бала булмый, бу авыру белән... Әмма мин дә гел нәрсәгәдер өмет иттем, нидер үзгәрер, дидем... Сиңа дөресен әйтергә телем әйләнмәде...

— Безнең икебездә бер авыру, Фәргать, — диде Гөлҗи-

һан, үксүеннән туктый төшеп. — Мине бу хакта Чиләбедә укыганда ук кисәткәннәр иде инде. Мин сиңа бу хакта әйтә алмадым.

— Мин дә...

Аларның икесенең дә җилкәләреннән таш төшкән кебек булды, әмма өсләрендә инде тау тора иде. Димәк, икесеннән дә бала булмый икән. Димәк, өмет тә бөтенләй юк. Моны алар икесе дә яхшы аңлый иде.

— Бәлки, балалар йортыннан берәр ятимне алып карарбыз? — диде Фәргать, Гөлҗиһанны юатырга теләп.

Гөлҗиһан шунда ук күз алдына Чиләбедәге гарип балалар йортын китерде, тәне калтырап куйды. Фәргать аны, өшеп киткән дип уйлап, үзенә якынрак тартты.

— Ашыкмыйк әле, Фәргать, — диде Гөлҗиһан, һаман нәрсәгәдер өметләнеп. — Әле безнең бит сәбәбенә керешкәнебез дә булмады... Яхшы табибларга күреник, икебез дә тикшереник.

— Бәлки, Аллаһтан сорап карарга кирәктер? — диде Фәргать, бөтенләй башка турында уйлап. — Әнә бит бүген яңгыр белән нәрсә булды. Безнең бит әле ул турыда уйлаганыбыз булмады.

Әйе шул, икесе дә дини гаиләдә үссәләр дә, аларның, намазга тезләнеп, бу хакта Аллаһтан сораганнары булмады. Шул больница тирәсеннән, Биташ суыннан ерак китә алмадылар. Бәлки, Фәргать дөрес әйтәдер, бәлки, аларга намаз укып, Аллаһтан үзләренә кирәкне сораргадыр?

— Фәргать, син намаз укырга каян өйрәндең? — дип сорады Гөлҗиһан, иренең кырда намаз укуын искә төшереп. — Син бит бөтен тәртибен белеп укыдың бүген.

— Караболакта яшәгәндә үк, картнәйдән өйрәнгән идем, — диде Фәргать. — Мин аның белән ураза вакытында һәр көн сәхәргә тора идем. Миасска күчкәч тә, картнәй мине нык тотты. Менә шуннан хәтергә сеңеп калган инде. Сөнкүл больницасында ятканда да, эчтән гел шул догаларны укып яттым. Исән калуыма, бәлки, шуларның да ярдәме тигәндер.

— Мин дә картнәй белән сәхәр ашарга тора идем, — дип искә төшерде Гөлҗиһан сабый чакларын. — Бер елны ураза вакытында хәтта күк капусы ачылганын да күрдем. Шунда мин төшемдә сине дә күрдем бит, Фәргать, ышанасыңмы? Өч яшемдә мин сине инде үземнең ирем итеп төшемдә күргән идем. Безнең яныбызда бик матур балаларыбыз да бар иде.

— Безнең балаларыбыз булачак, Гөлҗиһан, — диде Фәргать, нык ышаныч белән. — Күңелем шулай сизә, булачак безнең балаларыбыз, Алла теләсә.

— Әллә без дә намаз укып, Аллаһтан сорап карыйкмы соң? — диде Гөлҗиһан, иренең тел төбен аңлап. — Әнә бит

яңгыр белән нинди могҗиза булды. Әйдә, чишмә суы белән бит-кулларыбызны юып, укып карыйк әле!

Алар, тезләнеп, Аллакүл чишмәсендә юына башладылар. Кулларын, битләрен, авыз-борыннарын, чәч-башларын, терсәкләрен, колакларын, аякларын — барысын да өчәр тапкыр яңадан юдылар. Нәкъ бәләкәй чакта әби-бабалары өйрәткәнчә. Һәм шулхәтле чистарынып, сафланып киттеләр, әйтерсең лә яңадан бер кайгысыз сабый чакларына кайттылар. Гөлҗиһан, башын тау куышыннан тыгып, Чиләбе ягын тапты, чөнки кыйбла шунда иде. Аннан, эчкәрәк кереп, коры урынга барып бастылар. Фәргать — алга, Гөлҗиһан аның артына басты. Гомерләрендә беренче тапкыр, ялгыз калып, алар ирле-хатынлы Аллаһ каршында тезләнделәр. Тезләнүләренең сәбәбе — бала иде, нәсел калдыру теләге, үзләреннән соң тормышны, бу дөньяны дәвам итүчеләр калдыру өмете иде.

Фәргать бераз калтыранган һәм каушаган тавыш белән, куыш авызына таба борылып, азан әйтә башлады. Гөлҗиһан эчтән генә аның артыннан кабатлап барды. Тышта яңгыр тагы көчәеп китте, ахры, тау түбәсеннән шаулап шарлавык ага башлады. Дөнья белән ике арада судан пәрдә барлыкка килде. Бу хәл эчтәге күренешне тагы да серле итте, ир белән хатынны тышкы дөньядан бөтенләй аерып куйды. Әйтерсең лә туфаннан соң Уралтаудан төшкән беренче Алып адәмнәр, тау куышына кереп, беренче гыйбадәтләрен кылалар. Исән-сау калганнары өчен Аллаһка рәхмәт әйтәләр. Тау куышында әллә беренче кешеләрнең, әллә соңгыларының дога гыйбадәтләре яңгырый.

«Әлхәмдүлиләһи-раббил-галәмиин. Әррахмәнир-рахиим. Мәлики-яумиддин. Ияякә-нәгбүдү-вә-ияяккә-нәстәгыйн. Иһдинәссыйратал-мүстәкыйм. Сыйратал-ләзинә-әнгамтә гәләйһим гайрил-мәгъдүби-гәләйһим-вәләддаллиин. Амин.»

Урам якта җил-яңгырлар, күл һәм чишмә сулары, шаулап, куыш эченнән килгән доганы кабатлый:

«Бар мактаулар галәмнәр Раббысы, рәхим-шәфкать Иясе, кыямәт көненең Хуҗасы Аллаһы Тәгаләгә тиешле. Әй, Раббыбыз, без Сиңа гына гыйбадәт кылабыз вә Синнән генә ярдәм сорыйбыз. Безләрне туры юлга чыгар. Ул юлны Син бездән әүвәлгеләргә изге нигъмәт итеп бирдең. Сине ачуландырган һәм адашканнар юлыннан безне сакла. Амин.»

Фәргать белән Гөлҗиһан, кулларын күккә күтәреп, дога кылалар, Аллаһтан нәселләрен дәвам итәрлек иманлы балалар сорыйлар. Аларның эчкерсез күңелдән кылган догаларын фәрештәләр җиде кат күккә алып менеп китәләр. Изге догалар өчен күк капкалары берәм-берәм ачыла башлый. Җиде кат күкләрдә Фәргать белән Гөлҗиһанның нәсел шәҗәрәсе языла.

Җәйге яңгыр ничек кисәк башланса, шулай кинәт туктап та калды. Ул арада ялт итеп кояш килеп чыкты, суга манчылган җир өстен парландырып җылыта, кыздыра башлады. Ниндидер татлы һәм серле йокыдан уянып киткәндәй, Фәргать белән Гөлҗиһан сафланып, терелеп тау куышыннан йөгереп чыктылар. Урамда инде гөрләвекләр челтерәп ага, алар һәр тарафтан Аллакүлгә коялар иде. Күк йөзе исә тагы да тирәнәеп, җәелеп киткән кебек. Күл тирәсендәге зәңгәр балчык та камыр кебек йомшарган, изрәп, килеп кагылганнарын көтеп ята. Аяк киемнәрен кулларына тотып, алар юеш кыр буйлап кайтырга чыктылар. Җәйге рәшә һәм җирдән күтәрелгән җылы пар аша Караболак яшел утрау кебек күренә иде, ул әйтерсең лә чайкалып үзе аларның каршына килә. Фәргать белән Гөлҗиһан могҗизалар иленнән, серле дөньядан кайтып киләләр, шул томан эченнән йөзеп баралар. Яннарыннан туачак балаларының рухлары очып килә. Алар артыннан оныклар тезелешкән. Оныклар артыннан аларның балалары һәм оныклары... Беренче, икенче, өченче буыннар... Алып Ханнар нәселенең дәвамчылары... Караболак татарларының ишле нәселе. Туфаннан да исән калган Нух пәйгамбәр варислары — Фәргать белән Гөлҗиһанның балалары, балаларының балалары.

Фәргать белән Гөлҗиһан күрми — бу нәсел артыннан, инде кабып йотарлык булып, ажгырып аждаһа ашыга.

Атом аждаһасы.

Кешеләр үзләре үк шешәдән чыгарган радиация үләте. Үзенең агулы төкереге белән, ул юлында очраган һәр ташка, агачка, елга-суларга, җиргә һәм адәм балаларына үлем тамгасы салып бара. Ул инде ярты дөньяны тамгалаган, хәзер Алып Ханнар нәселе артыннан куа. Мәңгелектән бу җирләрдә бәхетле гомер иткән татарларга әҗәл тамгасы салырга ашыга атом аждаһасы. Аның агулы сулышыннан тирәякка үтергеч радиация тарала.

## Өченче бүлек

Радиация...

Күзгә күренми торган үлем.

Караболак халкы моңа кадәр бу хакта берни белмәде. Һәрхәлдә, Урал тауларында, уран өстендә утырса да. Чөнки халык җир астында яткан бу дәһшәткә беркайчан да кагылмады, ул да аларга тимәде.

Һәм кешеләр килеп, аны җир астыннан актарып чыгардылар. Ураннан ясалма юл белән плутоний алырга өйрәнделәр. Шулай итеп дөньяга радиация дигән гыйфритне өстерәп чыгардылар.

Ул хәзер бөтен җирдә дә бар — җирдә дә, күктә дә, суда да, кешенең үзендә дә. Әмма бу хакта кешеләрнең күпчелеге белми. Шулай ук нидән кинәт чирләп киткәннәрен дә белмиләр, нидән үлгәннәрен дә белмиләр...

Радиация атом-төш коралы белән бәйле бөтен җирдә бар, ул шулай ук атом электр станцияләрендә, су асты атом көймәләрендә, ракеталарда, хәрби полигоннарда бар. Нефть белән бергә җир астыннан уран радиациясе дә чыга, шуңа күрә нефть белән рак авырулары җитәкләшеп йөри. Бөтен дөньяны кырып килгән яман шешнең төп сәбәбе — радиация. Уранны җимереп тапкан бу радиоактив матдәләр туфракта һәм суда мең биш йөз ел яшиләр.

Дөнья галимнәренең әйтүе буенча, элеккеге СССРда илле ел эчендә рактан илле миллион кеше үләчәк. Россиядә исә төп радиация чыганагы һәм яман шешнең сәбәпчесе булып «Маяк» атом берләшмәсе тора.

Радиациянең тагы нинди чирләр тудырасын, кайсы яктан китереп бәрәсен әле беркем белми.

Шуңа күрә Мәскәү, Чиләбе, Иртәш-Озерскийның яшерен больницаларында, Снежинский-Сөнкүлнең НКВД лабораторияләрендә радиация нәтиҗәләрен җентекләп өйрәнәләр, кешеләр өстендә тереләй тәҗрибәләр үткәрәләр.

Милләтнең газиз балалары Фәргать белән Гөлҗиһан менә шушы атом казанында тереләй кайныйлар, аждаһа авызында булса да нәсел калдырырга тырышалар.

Аларны Аллаһ рәхмәтеннән ташламасын, ни булса да, сабырлыклар бирсен. Чөнки алар өчен зур сынаулар әле башлана гына. Бу гаиләнең ишеген бәхет һәм бәхетсезлек бергә шакый.

Гөлҗиһан Иртәш больницасында игезәк балалар тапты.

Тупырдап торган таза малай белән кызны шунда ук аның үзенә күтәреп күрсәттеләр. Балалар исән-сау, дүрт саннары да үз урынында иде. Гөлҗиһан, җиңел сулап, урынына ятты — иң мөһиме, балалар гарип түгел. Аны эчтән борчып торган тагы бер нәрсә калды — балаларның күзләре. Күрерләрме икән алар якты дөньяны, әллә, әтиләре кебек, аннан мәхрүм булырлармы? Бер караганда, Фәргать тумыштан сукыр түгел бит, ул, армиядә хезмәт иткәндә, шушы хәлдә калган. Аларның икесенең дә нәселендә гарип-гораба юк, барысы да алыптай нык, тазалар, озын гомерле.

Шулай булгач, нигә балалары өчен болай ут йота соң ул, туганчы ук аларның гарип булуларыннан курыкты, хәзер дә гел шул турыда гына уйлый. Моның сәбәбен белә Гөлҗиһан, чөнки ул үзе дә, ире дә — авырулар, аларда нурланыш тамгасы бар. Ә андыйларның балаларын Чиләбедә күреп кайтты инде Гөлҗиһан. Монда да андый балалар көн саен туып

тора, аларны күргәч, ата-аналары хуштан язып егылалар. Әмма баласының ни өчен гарип туу сәбәпләрен ата-аналарына әйтмиләр иде, гаепне аларның үзләренә сылтап калдыралар. Имеш, саф һавада аз булганнар, дөрес тукланмаганнар, гимнастика ясамаганнар. Ике башлы, балык койрыклы балалар шуңа туа икән. Әмма Гөлҗиһан моның сәбәбе бөтенләй башкада икәнлеген белә иде инде һәм шуңа күрә, коты очып, балаларының күзенә күренүен көтте.

Аларның таза-сау икәнлекләрен белеп, Гөлҗиһан сөенеп бетә алмады.

Беренче тапкыр имезергә китерү белән, ул аларны чишендереп ташлады һәм бөтен җирләрен тикшереп чыкты. Кызының да, улының да бөтен нәрсәсе урынында иде. Гөлҗиһан аларның текәп күзләренә карарга тырышты, әмма сабыйлар, песи балалары кебек, әле күзләрен юньләп ача да алмыйлар. Әмма имә башлагач, ул аларның үзенә текәлеп карауларын күрде. «Күрәләр, әлбәттә, күрәләр, әнә бит ничек игътибар белән тирә-якны карыйлар!» — дип уйлады әни кеше. Ул аларга төрле матур исемнәр белән дәшеп карады, колак төпләрендә күгәрчен кебек гөрләде, тик балалар аның сүзләренә игътибар итмәделәр, мышкылдап имүләрен белделәр.

Берничә көннән соң табиблар үзләре кереп Гөлҗиһанга барысын да аңлаттылар — балалар бөтен яктан да сау-сәламәт, күзләре дә бик яхшы күрә иде. Әмма... Әмма аларның нигәдер хәзергә тавышка реакцияләре юк икән, ягъни икесе дә ишетмиләр кебек. Гөлҗиһанның, өнсез калып: «Бу нәрсә булырга мөмкин соң?» — дигән соравына, инде күпне күргән табиблар сабыр гына: «Хәзергә өздереп әйтүе авыр, — диделәр. — Хәзергә алар ишетмиләр кебек...»

— Ишетмәгәч, сөйләшә дә алмый бит инде алар! — дип өзгәләнеп сорады Гөлҗиһан. — Минем балаларым телсез-чукрак булып туганмыни?!

— Ул хәтлесе үк алга таба билгеле булачак, — дип, аны юатырга тырыштылар табиблар. — Дөньяда әллә нәрсәләр була. Бәлки әле телләре дә ачылыр, ишетә дә башларлар. Бу вакытлы гына хәл булырга мөмкин.

Бала имезә торган анага борчылырга ярамаганын белсә дә, бу хәбәрдән Гөлҗиһан телсез-өнсез калды. Тамагына ризык бармады, йокысы качты. Үзе дә шушы больницада эшләп, Гөлҗиһан мондый очракларны инде шактый күргән иде. Сабыйларын тагы бер тапкыр бик җентекләп тикшергәннән соң, Гөлҗиһан барысын да аңлады — аның балалары тавыш ишетмиләр иде. Бу исә... Бу исә тумыштан телсез-чукрак булуны аңлата. Аның балалары телсез-чукрак булып туганнар иде. Алар беркайчан да бер сүз ишетмәячәкләр һәм бер сүз әйтә дә алмаячаклар иде.

Бу хакта ул башта Фәргатькә әйтмәде, чөнки иренең куанычы, бәхете дөньяга сыярлык түгел иде. Аның бит хәзер тупырдап торган ике баласы бар, ул хәзер әти кеше һәм ул шушы бәхет белән яши иде. Гөлҗиһан аны хәзергә борчымаска булды, күңеленнән ниндидер могҗизага да ышанды, нидер көтте. Вакыты җиткәч, аның сабыйлары да «әттә», «әннә» дип әйтә башлар кебек тоелды. Чөнки башкача була алмый бит, бала ата-анасының тавышын ишетеп үсәргә тиеш, бала үз телендә беренче сүзләрне әйтергә тиеш. Алар нәселендә, Караболакта, кешелек тарихында гел шулай булган, шулай тел, милләт тормышы буыннан буынга тапшырылган. Аның балалары гына үз ана телләрендә сөйләшүдән, татарча моңнардан мәхрүм була алмый бит инде! Юк, дөньяда мондый гаделсезлек булмас, беркөн аларның теле ачылыр, сөйләшә башлarлар дип өзелеп көтте Гөлҗиһан. Тик көткән могҗиза һаман булмады. Балалар елыйлар, үзләренчә көләләр, тик тавышны ишетмиләр, бернәрсәгә дә җавап-реакцияләре юк иде.

Күзләре күрмәгәч, Фәргать башта моны аңламады.

Әмма вакыты җитеп тә, балалар һаман бер сүз әйтмәгәч, ул аптырый, борчыла башлады. Һәм Гөлҗиһан аңа дөресен әйтеп бирергә булды — аларның балалары телсез-чукрак булып туган иде. Һәм мәңге сөйләшә алмаячаклар иде...

Фәргать бу хәбәрне бик авыр кабул итте. Ул башта моңа ышанырга теләмәде.

Өйгә төрле табибларны чакыртып карадылар, белгән кешеләргә күрсәттеләр. Әмма берсенең дә җавабы өметле түгел иде. «Балалар бөтен яктан сәламәт, әмма тумыштан телсез-чукрак. Ягъни ишетмәячәкләр дә, сөйләшмәячәкләр дә...» Бу хәбәр Фәргатьне чалгы белән чабып еккан кебек булды. Ул барысын да көтте, авыру булырлар дип тә уйлады, әмма балаларының мәңгегә телсез-чукрак буласыларын ул күз алдына да китерә алмады.

Күзләре күрмәгәч, ул балаларын тавышлары аша танырга хыялланган иде. Әмма алар телсез булып чыкты. Алар әтиләренең әйткән сүзләрен ишетмәячәкләр, аңа беркайчан да җавап кайтармаячаклар. Бер өйдә өч гарип — бер сукыр, ике телсез-чукрак. Һәм барысына да Фәргать үзе гаепле, мондый авыруы, мондый диагноз белән, ул Гөлҗиһанны бала табарга өндәргә тиеш идеме соң? Хәзер нишли инде ул бу өч гарип белән?

Тормышында нинди авырлыклар күреп сынмаган Фәргать бала кайгысыннан сыгылып төште. Аның өчен яшәүнең мәгънәсе югалган кебек булды, өмете өзелде. Бу хәлләрдә үзен гаепләүдән аның күңеле телгәләнде, әмма инде ялгышны төзәтеп булмый иде. Үзе дә авыру Гөлҗиһан кулына

язмыш тагы ике гарип бала китереп тоттырган иде. Һәм моңа Фәргать үзе сәбәпче булды. Югыйсә алар Аллаһтан тезләнеп бала сораганнар иде бит, сәламәт бала дип әйтергә оныткаңнар, ахры...

Ул көнне Фәргать эштән вакытында кайтмады.

Әле аның белән моңа кадәр беркайчан да андый хәлнең булганы юк иде. Соңгы вакытта Фәргатьнең бик нык күңелсезләнүен, эчтән өзгәләнүен сизеп йөрде Гөлҗиһан. Балаларның шундый булуларын белгәннән соң бик бетеренде ул. Күзләре күрмәгәч, ул аларның тавышларын ишетермен дип хыялланганды, ә балалар телсез булып чыктылар. Аларның мондый булып тууларына Гөлҗиһан тулысынча үзен гаепләде, әмма, нинди генә булсалар да, ул аларны үлеп ярата иде. Аларның нинди матур, сөйкемле балалар икәнлеген күрсә, Фәргать тә тынычланыр, балаларын ничек бар, шулай кабул итәр һәм яратыр иде. Әмма ул аларны күрми шул. Тавышларын ишетми. Җаннарын тоймый. Балаларның мондый булып тууы Аллаһтан бер сынау инде, әмма Фәргатьнең бу хәлләр белән килешәсе килми кебек.

Бу көннәрдә Гөлҗиһан үзе дә авыртынып тора иде. Чөнки берьюлы ике бала тугач, өйдә мәшәкать күзгә күренеп артты, элеккеге җайланган тәртип бозылды. Хәзер Гөлҗиһанга орчык кебек бөтерелергә туры килә, балаларны да карарга, Фәргатьне дә көйләргә кирәк. Фәргать күрмәү сәбәпле, өйләнешкәч Гөлҗиһан бөтен йорт мәшәкатьләрен үз өстенә алган иде. Кибеттән азык-төлек алу, базарга бару, йорт кирәк-яракларын тулыландырып тору, почтасына-мазарына йөгерү — барысы да Гөлҗиһан өстендә иде. Балалар тугач, ул барысына да өлгерми башлады, сугылды, бәргәләнде һәм өзлегеп китте. Температурасы күтәрелде, сөте бетте, туктаусыз укшый, коса башлады. Әле ярый Таифә җиңгәсе килеп йорт эшләрендә ярдәм иткәли башлады, югыйсә Гөлҗиһан бөтенләй урын өстенә яткан булыр иде. Шушындый вакытта Фәргатьнең дә кәефсезләнеп йөрүе, инде эштән үк кайтмый калуы Гөлҗиһанны тагы борчыды, тагы утка салды. Гаиләдә көтелмәгән күңелсез хәлләр өлгереп килә кебек. Әмма мондый бәлагә юл куярга ярамый иде. Инде төн уртасы җитеп килә, ә Фәргать һаман юк. Соңгы вакытта ул эштән шактый соңга калып һәм салгалап кайта башлаган иде. Әгәр шушы юлга кереп китсә, Фәргать үзе дә бетәчәк, Гөлҗиһанны да бетерәчәк. Гөлҗиһанны бу дөньяда Фәргатькә һәм балаларына мәхәббәте генә тотып тора, шулар бетсә, ул да юк. Һәм авыру Гөлҗиһан, урыныннан кубарылып, балалары янында күрше хатынны калдырып, төн уртасында Фәргатьне эзләп чыгып китте.

Күңеле белән нидер сизенеп, Гөлҗиһан шәһәрнең төнге

рестораннары буйлап китте, чөнки ул Фәргатьнең соңгы вакытта сыра белән мавыга башлавын күргән иде. Башта ул моңа игътибар бирмәскә тырышса да, хатын-кыз буларак белде — эчү сырадан башлана. Медицина да шуны раслый. Фәргать белән дә шулай килеп чыкмагае...

Гөлҗиһан дөрес сизенгән икән — үзәк ресторанда ул Фәргатьнең ярым буш залда берьялгызы бөкерәеп утыруын күрде. Аның алдында инде шактый бушый төшкән аракы шешәсе иде. Кызганып һәм куркып, Гөлҗиһан читтән генә ирен күзәтеп торды, чөнки аның беркайчан да Фәргатьне мондый хәлдә күргәне юк иде. Фәргать тын гына елый иде.

Гөлҗиһан әкрен генә аның янына килеп утырды, аракы шешәсен бер читкә алып куйды. Хатыны бер сүз дәшмәсә дә, Фәргать аны шунда ук таныды. Гөлҗиһаннан бала имезгән сөт исе, өй исе килеп тора иде. Аннан җан җылысы бәреп тора иде.

— Безгә кайнар чәй белән берәр татлы ризык китерегез әле, — диде Гөлҗиһан, берни булмагандай, өстәл янына килеп баскан официанткага.

— Әйе шул, әнисе, чәй эчәсе килә, — диде Фәргать тә, теле көрмәкләнүен Гөлҗиһанга сиздермәскә тырышып.

Кара-каршы утырып, өйдәге кебек бергәләп чәй эчтеләр.

Гөлҗиһан теш агартып Фәргатькә берни әйтмәде, аны бернәрсәдә гаепләмәде, сәрхушлеге турында гомумән кузгатмады. Алар, берни булмагандай, матур гына сөйләшеп утырдылар, әйтерсең лә кечке якта ресторанга чәй эчәргә махсус килгәннәр. Фәргать бераз айный төшкәч, Гөлҗиһан аны иплəп кенә култыклап алды, такси чакыртып, тиз арада өйләренә дә кайтып җиттеләр. Гөлҗиһан аны үзе чишендерде, балалар кебек, әйбәтләп юындырды, йокларга салды. Ул көнне Гөлҗиһан аңа берни әйтмәде. Хәзер инде Гөлҗиһанның үз хәле хәл иде. Бу көннәрдә каты авырып йөрүләре, кечке киеренкелек, Фәргатьне эчкән хәлдә күрү аның җанына, йөрәгенә китереп суккан иде. Фәргатьне йокларга салганда, ул инде аңын җуя барганын сизде, үрмәләп балалары янына килде һәм аларның аяк очларына ауды. Авыру аны җиңгән, өстенә менеп утырган, бала чактагы кебек, бугазыннан алган һәм кара упкынга өстери иде...

Гөлҗиһан шулай ярым аңсыз хәлдә идәндә шактый озак ятты.

Ул балаларның шыңшып елауларын да, Фәргатьнең авыр сулап, уһылдап әйләнгәләвен дә ишетмәде. Башта ул бик тирән упкынга очты, инде җиргә төшеп, чәлпәрәмә киләм дигәндә, аяк астында Аллакүлнең йомшак зәңгәр балчыгын күрде. Ул тирә-яктагы караңгылыкта көмеш нурлар чәчеп, балкып ята иде. Гөлҗиһан аның өстенә тезләнгән хәлдә барып

төште, әйтерсең лә кемнеңдер әмере белән шулай сәҗдәгә китеп гыйбадәт кыла иде. Башын күтәреп караса, каршында ап-ак сакаллы, ап-ак чәчле бер карт басып тора. Ул Таһирҗан бабайга да бик охшаган, ул да түгел кебек. Күңеленең әллә кайсы почмагында бер уй килә, тукта, бу бит — картнәе сөйләгән Хозыр Ильяс! Ул гел шулай кешеләргә авыр вакытта юлларына чыгып ярдәм итә икән. Ул тере суы эчкән үлемсез карт... Бәлки, Яхшыларның берседер, алар да кешегә авыр вакытларында күренәләр бит... Гөлҗиһан нигәдер аңа үзенең үпкәсен белдереп калырга ашыга: «Нигә минем балаларым телсез-чукрак булып тудылар? — ди. — Мин бит аларны Аллаһтан дога кылып, намаз укып сорап алган идем...» Чал карт озак кына аңа карап тора, аннан нигәдер Таһирҗан бабасы тавышы белән җавап бирә: «Син Аллаһтан бала сорадың, сәламәт булсын дигән сүзне әйтмәдең, — ди. — Син гыйбадәтне үзеңә кирәккәндә генә кылдың, аннан Аллаһны оныттың, Аңа башка мөрәҗәгать итмәдең, — ди. — Бу сиңа сынау һәм җәза», — ди...

Картның бу сүзләреннән Гөлҗиһан шашынып кала, әмма аңа ничек җавап бирергә дә белми. Әйе, алар, бала кирәккәндә, Аллаһны искә төшерделәр, хәтта намаз укыдылар. Балага узганын белгәч, Гөлҗиһан әле карт-карчыкларга сәдака да өләште. Һәм шуның белән бетте, тагы дөнья йотты. Ул туктаусыз табибларга күренде, атна саен анализларын биреп торды, хисапка басты, әмма Аллаһ каршына яңадан басмады. Ул бит бу хакта белмәде дә, аңа әйтүче дә булмады.

«Әйе, сиңа әйтүче, исеңә төшерүче булмаган, — дип дәвам итте чал карт. — Шуңа күрә бу газапларың да мәңге булмас. Сабыр итәргә кирәк һәм Аллаһны онытмаска... Бу балаларның тууында хикмәт бар, алар сезгә җәннәт юлларын ачар...»

Бу сүзләрне әйтте дә юлаучы карт, юкка чыкты. Гөлҗиһан аны күпме генә чакырып караса да, җавап бирүче булмады. Гөлҗиһан авыр итеп ыңгырашты, тәне тагы ут булып яна башлады, караңгыда ул кая барырга белмичә бәргәләнде. Каяндыр — әллә күктән, әллә Аллакүл буеннан өзелеп-өзелеп бала елаган тавыш ишетелә иде. Гөлҗиһан караңгыда аларны эзли, әмма таба алмый икән. Бу гаҗизлектән ул үзе дә кычкырып елап җибәрә һәм күзләрен ача. Гөлҗиһан идәндә, бала караваты янында ята, янында шашынган, курыккан ире басып тора, өйдә игезәкләрнең шыңшып елаулары ишетелә иде.

— Әнисе, нәрсә булды сиңа бүген? — диде Фәргать, бу хәлләрдән бик нык куркып. — Мин сине баядан бирле уятырга тырышам, тормыйсың, үлгән кебек ятасың. Кулларың, тәнең дә сап-салкын. Мин инде табиб чакыртмакчы идем.

— Кирәкми, үтте инде, — диде Гөлҗиһан, чайкала-чайкала торып басып.

Ул елап шешенеп беткән балаларының тиз генә асларын алыштырды, чиста чүпрәккә төреп, чиратлап имезә башлады. Аның әле һаман башы әйләнә, авызында тимер тәме, күңеле болганып, күз аллары караңгыланып тора иде. Әмма балалары шулчаклы ачыкканнар, аларны ашатмыйча торып, үзең турында уйларга да мөмкин түгел.

— Хәзер чәй куярмын, Фәргать, — диде ул, иренә күтәрелеп карамыйча гына. — Син чыгып китәргә ашыкма әле, әйтер сүзем бар.

Фәргатьнең күңеленә шом керде. Ул кичәге хәлләрне бераз хәтерли, әмма Гөлҗиһан тавыш куптармагач, шул килеш үтеп китәр, онытылыр дип уйлаган иде. Ә Гөлҗиһанга бөтенләй әллә нәрсә булган — әле ул үлек кебек тора алмыйча ята, әле чыгып китмәскә куша. Тавышы ят, салкын, әйтерсең лә бөтенләй чит кеше. Ничә ел бергә торып, Фәргать беренче тапкыр хатынының шундый салкын тавышын ишетә. Һәм гомерендә беренче тапкыр Фәргать шундый уңайсыз, аңлаешсыз хәлдә калды. Нигәдер гаебе дә бар кебек, алай зур гаебен дә күрми. Ә күңел тырный, йөрәк борчыла.

Балаларын ашаткач, Гөлҗиһан үзен рәткә китерде, аннан чәй куеп җибәрде, табын әзерләде. Ул арада Фәргать тә юынып, кырынып өстәл янына килеп утырды. Тыштан тыныч кебек күренсә дә, эчендә һаман нindидер шом, хәвеф бар иде Фәргатьнең. Кичәге хәлләрдән соң Гөлҗиһан үзен ничек тотар? Ул шулай нинди җитди нәрсә әйтергә әзерләнә икән? Сүзе бар икән, нигә һаман суза?

Гөлҗиһан башта дәшми генә иренең тамагын туйдырды, инде чәйләр эчеп бетергәч, җитди сүзенә күчте.

— Миндә кан авыруы, Фәргать, өченче дәрәҗә яман шеш, — диде ул, ниндидер чит тавыш белән. — Мин рак белән хисапта торам. Бу авыру теләсә кайсы вакытта алып китәргә мөмкин.

Әйтерсең лә Фәргатьнең башына күсәк белән китереп ордылар. Ул шактый вакыт бернәрсә әйтә алмыйча утырды.

Гөлҗиһан бернәрсә сиздермәде бит! Фәргать аның авырып ятканын да, ыңгырашып, уфтанып йөргәнен дә хәтерләми. Ул һәрвакыт шат күңелле, бөтенесен булдыра, бөтенесен өстерәп, ерып бара. Ә шуның артында нинди авыр хәлләр, нинди куркыныч чир. Һәм ул теләсә кайсы вакытта Гөлҗиһанын алып китәргә мөмкин. Бу исә Фәргать өчен дә, балалар өчен дә тереләй үлем дигән сүз бит.

— Шуңа күрә, — дип дәвам итте Гөлҗиһан, күз яшьләрен чак тыеп. — Шуңа күрә синең исән булуың бик кирәк. Бигрәк тә — балалар өчен. Без дүртебез дә авыру бит, Фәргать...

Шулай диде дә Гөлҗиһан, тыела алмыйча үксеп елап җибәрде. Фәргатьнең аны мондый хәлдә бер дә күргәне юк иде, ул да шашып калды. Хатыны әйткән сүзләр аның миендә кайнады, җанын газаплады, башында бер генә уй калды: «Гөлҗиһан каты авыру. Ул теләсә кайсы вакытта үлеп китәргә мөмкин». Мондый хәлнең булуына ышанасы килми, чөнки Гөлҗиһан һәрвакыт ут кебек тере, ялкын чәчеп торган үткен кыз иде бит! Шушы хәтле авыру бер көндә генә килми бит инде, димәк, бергә яши башлаганда ук инде ул шулай газапланган. Ә Фәргатькә берни сиздермәгән, гел аның турында кайгырткан.

— Син алай бетеренмә әле, әнисе, — диде ул, Гөлҗиһанны күкрәгенә кысып. — Хәзер кемдә авыру юк инде, бигрәк тә биредә? Үзең әйтәсең бит, бөтен больница авыру белән тулган, дисең. Әле без аякта, Аллага шөкер, урын өстендә ятучылар да күп бит әле. Иң мөһиме — син борчылма, бөтен авырулар нервыдан килә, үзең миңа шулай дия идең бит.

Гөлҗиһан яшьләрен сөртеп куйды. Әйе, борчылып, бәргәләнеп кенә бу авыруны бетереп булмый инде, ә бөтенләй аяктан калырга мөмкин. Әмма Гөлҗиһанның Фәргатькә әйтер сүзе бу түгел иде бит, әгәр кичә эчмәгән булса, Гөлҗиһан авыруы турында, бәлки, иренә беркайчан да әйтмәгән дә булыр иде. Фәргатьнең соңгы вакытта хәмер белән булаша башлавы Гөлҗиһанны бик нык куркытты, хәвефкә салды. Дөрес, биредә күп кеше эчә, имеш, аракы радиациядән булыша дип, аны махсус шулай тараталар. Әмма бу хәл алар гаиләсенә ярамый, арага аракы керсә, аларны бетерәчәк. Башкалар кебек Фәргать тә эчә башласа, авыру Гөлҗиһан белән, телсез-чукрак балалары белән, сукыр Фәргатьнең үзе белән нәрсә булыр, алар кемгә кирәк?

— Син эчмә, Фәргать, югыйсә барыбыз да харап булабыз бит, — диде Гөлҗиһан. — Миңа да, сиңа да артык борчылырга ярамый, авыруыбыз шундый. Син эчә башласаң, мин дә сынармын, чөнки минем дә көчем кимеп бара. Ә кулда балалар. Бездән башка алар беркемгә кирәкми. Аларга бит аеруча тәрбия, аеруча игътибар кирәк. Син шушы юлга бассаң, без барыбыз да бетәбез.

Хатынының бу сүзләреннән Фәргать тетрәнеп китте. Ул Гөлҗиһанга ни дип җавап бирергә дә белмәде, чөнки хатыны хаклы иде. Аларның моңа кадәр нык дип йөргән тормышлары бер мизгелдә таркалып юкка чыгарга мөмкин иде. Фәргать моны сукыр күзләре белән дә күргән кебек булды. Аңа үзләре өчен, уртак тормышлары өчен, балалары өчен бик куркыныч булып китте. Әйе, ул үзе — дөм сукыр, Гөлҗиһанда — рак, балалары — телсез-чукрак. Бу тормыш бераз гына саксызлыктан, ялгыштан да җимерелеп төшәргә мөмкин.

Артык йомшарудан, гел төшенкелеккә бирелүдән, бәхетсезлек турында гына уйлап торудан да таркалырга мөмкин бу тормыш. Моңа кадәр барысы да Гөлҗиһанның батырлыгы һәм тәвәккәллеге белән барды, ул беркемгә сер бирмәде, бернәрсәдән зарланмады, беркайчан тормыштан өметен өзмәде. Авыру балалары тугач, һәм аларның мәңгелек гарип икәнлекләрен белгәч, аңа да әллә нәрсә булды, кинәт кенә бирешеп китте. Юк, моңа балалар түгел, Фәргатьнең соңгы вакытта үз-үзен тотышы сәбәпче булгандыр.

Гөлҗиһанның мондый хәлдә калуына Фәргать тулысынча үзен гаепләде. Нинди шайтан котыртты соң аны аракы шешәсенә барып ябышырга? Әйтерсең лә аннан тормыш җиңеләя, Фәргать күрә, балалар сөйләшә башлый. Юк, аракы эчеп кенә андый могҗиза булмаячак, ә бөтенесе юкка чыгарга мөмкин. Димәк, аларга шушы язмышлары белән ризалашып, булганына шөкрана итеп, булмаганына зарланмыйча, сабырлык белән яшәргә өйрәнергә кирәк. Һәм гаиләдә, тормышта үрнәкне ул — ир кеше, әти кеше күрсәтергә тиеш. Гөлҗиһанга да ул хәзер шушы сүзләрне әйтер, аны шулай дип юатыр, юкса анда да тимер йөрәк түгел бит, бер өзелергә дә мөмкин.

— Нәрсә теләсәң, шуның белән ант итәм, Гөлҗиһан, башка бу эш кабатланмаячак, — диде ул, бөтен җитдилеге белән. — Бу хакта башка борчылма. Ә тормыш турында син хафаланма, барысы да яхшы булыр, менә күрерсең. Торырга урыныбыз бар, һөнәребез, белемебез бар, гаиләбез тату, инде балаларыбыз да бар, шулай булгач, нигә төшенкелеккә бирелергә? Бездән авыр хәлдәге кешеләр дә бар бит әле, үзең көн саен күреп торасың. Алар да яши.

— Шулай инде, — диде Гөлҗиһан, тынычлана төшеп. — Безнең балалар әле Аллага шөкер, Фәргать, менә мин Чиләбедә күрдем ул гарип балаларны. Алла сакласын. Ике башлы, бер күзле балаларга хәтле бар. Бу игезәкләр безгә Аллаһтан бер сынау инде ул.

Һәм Гөлҗиһан кинәт кенә бүген төнлә күргән төшен исенә төшерде. Теге ак бабай да шулай диде бит: «Бу балаларыгыз сезгә сынау һәм җәза, — диде. — Алар сезгә җәннәт юлына сәбәпче булырлар...» — диде.

— Мин бүген бер сәер төш күрдем, — диде ул, иренә сыенып утырып. — Төшемдә яныма бер чал карт килде. Мин аннан: «Нигә безнең балаларыбыз шундый булып туды? Без бит аларны, намаз укып, Аллаһтан сорап алган идек...» — дип сорадым...

— Ә ул нәрсә диде?

— «Сез гыйбадәтне үзегезгә кирәктә генә кылдыгыз, аннан Аллаһны онытгыгыз...» — диде. «Бу сынау һәм җәза...» —

диде. Хозыр Ильяска охшаган ул карт сабыр итәргә һәм Аллаһны онытмаска кушты... «Бу балаларыгыз сезгә җәннәт юлларын ачар» — диде.

— Бик хикмәтле төш күргәнсең син, — диде Фәргать, уйга калып. — Мин үзем дә соңгы вакытта бу хакта гел уйланып йөри идем. «Аллаһтан намазлар укып сорадык, ә ул безгә гарип балалар бирде» дип. Көфер сүз инде, әлбәттә, хәзер үзем дә аңладым. Әмма күңел вәсвәсәле бит, әллә ниләр уйлата. Менә хәзер аңладым мин. Дөрес әйткән ул карт — без үзебезгә кирәккәндә генә Аллаһны искә алабыз шул. Менә шуңа күрә сынау һәм җәза инде болар безгә. Әмма сабыр итәргә кирәк, Гөлҗиһан. Нинди булсалар да, алар безнең балалар, йөрәк җимешебез, мәхәббәт җимешләре. Аларның мондый булып тууларында да без белмәгән берәр хикмәт бардыр әле. Безнең картнәй әйтә иде: «Мөселман кешегә нәрсә булса да, хәерлегә була», — дия иде.

— Таһирҗан бабай да гел шулай дип әйтә, — диде Гөлҗиһан. — Алар янына да кайтып килергә кирәк, Фәргать. Балалар тугач, без бөтенләй авылны да оныттык. Кайтып, Коръән укытып, сәдакалар биреп килергә кирәк. Әле балаларның мулла кушкан исемнәре дә юк бит, загста гына яздырып кайттык.

— Әйе шул. Безнең картнәй әйтә иде, кыямәт көнендә балалар үзләренең һәм аталарының исемнәре белән Аллаһ каршына чакырылачаклар, дип. Минем колагыма исемне, әле Караболакта яшәгәндә үк, Таһирҗан бабай кушкан.

— Миңа да! — дип сөенеп әйтте Гөлҗиһан. — Безнең балаларга да Таһирҗан бабай исем кушар, Алла боерса. Бу ялда ук Караболакка кайтыйк, Фәргать? Үзем дә бик сагындым авылны.

Бу тәкъдимне Фәргать тә сөенеп кабул итте. Чөнки соңгы вакытта аның тормышы буталып, әллә нинди юлларга кереп китеп бара иде. Аның үзенә дә, Гөлҗиһанга да, балаларына да олылар сүзе, өлкәннәр ярдәме кирәк иде. Таһирҗан бабайлар догасы кирәк иде. Киләсе атнага кайтырга исәпләп, бу хакта авылга хәбәр итеп тә куйдылар.

Гөлҗиһанга тагы җан керде. Ул тагы элеккеге ут Гөлҗиһанга әйләнде. Аңа бәхет өчен нибары өмет чаткысы да җитә иде. Бүген, бу мизгелдә бәхетле булу да җитә иде. Ул өй эчендә яңадан орчык кебек бөтерелә башлады. Аның терелеп, яшәп, яшәреп китүен сизеп, Фәргать тә бераз тынычланды. Әмма бу хәлләрдән, бу сөйләшүдән ул үзенә зур сабак алды. Ул бөтен гаиләнең, шул исәптән Гөлҗиһанның да үзенә карап торуын аңлады. Тыштан бөтен тормышны Гөлҗиһан алып бара кебек тоелса да, эченнән генә ул гел Фәргатькә таянган, аннан өмет иткән икән. Хатын-кыз гел ут булып

кына яши алмый шул, менә шундый вакытларда сыенып өчен ир кирәк. Акыллы, иманлы ир кирәк. Тыштан нинди уңган-булган, ялкын кебек Гөлҗиһанның да эче тулы хәсрәт, борчулы уйлар икән бит. Ә Фәргатьнең маңгай күзе генә түгел, күңел күзе дә сукыр булган, ахры, шуларны сизмәгән. Гөлҗиһан үзенең тәнендә һәм җанында нинди каты авырулар, көчле газаплар йөрткәнен белмәгән.

## Дүртенче бүлек

Караболакта аларны бик сөенеп каршы алдылар.

Фәргать белән Гөлҗиһан шактый еллар торганнан соң туган тансык балаларын күтәреп кайтканнар иде. Сабыйлар гаҗәп тереләр, таза-саулар, әти-әниләре кебек эре сөякле, гәүдәле булырга охшаганнар. Аларның телсез-чукрак булып туулары турында Гөлҗиһан берәүгә дә әйтмәде, бәхетсезлек турында нигә алдан хәбәр биреп куярга? Вакыты җиткәч күрерләр, белерләр. Бәлки әле, нindидер могҗиза булып, телләре дә ачылыр, Ходайның рәхмәте киң. Ә хәзергә аларның исәнлекләре өчен сөенергә кирәк, киләчәк өчен кайгырудан мәгънә юк. Хәзер Караболакта һәр ике йортның берсендә шушы хәл.

Бу кайтканда Гөлҗиһаннар урамыннан тагы берничә кешенең үлгәнлеге билгеле булды. Алар барысы да яшьләр яки ир уртасы кешеләр иде. Гөлҗиһаннар классыннан тагы берничә бала үлгән булып чыкты. Рәшидә исән икән, әмма вакыты-вакыты белән бик каты өянәкләре була башлаган, Гөлҗиһанның дарулары да ярдәм итми икән. Әти-әнисенең әйтүе буенча, авылда гарип балалар тууы арткан, кайсы тумыштан дөм сукыр, кайсылары телсез-чукрак, ди. Бу сүзләрне ишеткәч, Гөлҗиһан калтырап куйды. Чиләбедәге гарип балалар йорты исенә төште. Хәзер анда урнаштырыр өчен бер ел чират көтәргә кирәк иде, гарип балаларны өлкәнең Казакъстан чигендәге Троицк шәһәренә илтә башлаганнар.

Бу кайтуында Гөлҗиһан тагы шуңа игътибар итте — авылда өй аралаш бер каты чирле ята. Аларны инде больницаларга да алмыйлар икән, чөнки бөтенләй өметсезләр, ди. Кешеләрнең кайсы гөбе кебек шешенгән, кайсылары таяк кебек кипкән, кайсының аягы йөрми, кайсының башы эшләми. Һәм бернинди дару, карау юк, авыл халкы һаман Гөлҗиһан кайтарган аспириннарны икегә бүлеп эчеп ята. Соңгы вакытта бала, йорт мәшәкатьләре белән Гөлҗиһан да сирәк кайтты, эшләмәгәч, дарулары да сирәгәйде.

Бу хәлләрне күреп, Гөлҗиһанның җаны өзелде.

Үзләренә әйтмәсә дә, ул аларның күбесендә әҗәл чире —

яман шеш икәнлеген белде. Ә Коншакта, Чиләбедә аларга һаман «гомуми авыру» дигән мәгънәсез диагноз куялар, карамыйлар, тиешенчә дәваламыйлар. Әйтерсең лә аларга Караболак халкының менә шулай күпләп авыруы, күпләп кырылуы кулай гына. Ә халыкның күпчелеге газаплы үлемгә дучар ителгән, аерма шунда гына: кем иртәрәк китеп бара, кем әле шактый интегеп ята. Ничек ярдәм итәргә соң бу халыкка? Караболак өстенә ябырылып килгән бу әҗәл афәтен Гөлҗиһанның аз-маз дарулары белән генә җиңеп булмас бит. Халык ашаган ризыгыннан, эчкән суыннан агулануын белсә дә, аның башка чарасы юк, ул барыбер көн саен шуларны куллана. Белсә дә куллана, белмәсә дә куллана. Димәк, биредә дә Иртәштәге дошман — радиация хакимлек итә, халыкны шул кыра. Ә нишләргә? Кая барырга? Бу тирәдә бөтен тирә-якта шушы хәл бит. Гөлҗиһан бу сорауларына күптән җавап эзли инде, әмма таба алганы юк. Халык башына килгән бу бәлаләрдә ул кемнең гаепле икәнлеген дә белми. Нишләргә кирәклеген дә белми. Чөнки бу хәлләр әле ил күләмендә ачылмаган, фаш булмаган иде. Моның өчен әле дөньяга Чернобыль фаҗигасенең булуы кирәк иде.

Өйлә намазыннан соң Гөлҗиһаннарга, яшьләр кебек җилҗил атлап, Таһирҗан бабай килеп керде. Аның йөзенә карагач, Гөлҗиһан авып китә язды — Таһирҗан бабай яңадан балага әйләнеп бара иде! Аның йөзендә ник бер җыерчык калсын, битләре шоп-шома, үсмер малайларныкы кебек алсуланып ялтырап тора. Ак чәчләре яңадан коңгырт төскә кергән, сакалы да шундый ук. Бөтен авыл үлеп, кырылып ятканда, Таһирҗан бабай яңадан яшьлегенә, балалыгына кайтып бара түгелме соң?

— Таһирҗан бабай, нәрсә булды сиңа? — дип кычкырып җибәрде Гөлҗиһан. — Нишләттең син битеңне? Җыерчыкларың кая китте?

Бу сорауны Таһирҗан картка бер Гөлҗиһан гына бирми иде, күрәсең, ул серле генә елмаеп куйды:

— Битеңне көненә биш тапкыр Аллакүл суы белән юсаң, җыерчыклар бетә ул, кызым, — диде.

Бу аның көнгә биш тапкыр намаз укуына ишарә иде.

Җитмештән узган бабасын балалар кыяфәтендә күрү Гөлҗиһанны тетрәндерде, күңелендә әллә нинди уйлар уятты. Моның нинди хикмәте булыр икән? Югыйсә Таһирҗан бабасы да кеше эчкәнне эчә, кеше ашаганны ашый кебек. Башкалар шушы тормыштан үлә, ә ул яшәрүгә таба бара. Гөлҗиһан Иртәш читендә котырып үскән баш кадәр әрекмәннәрне, күлдәге кеше зурлыгындагы балыкларны күз алдына китерде. Болар да, табигый яшәешләрен онытып, башка төрле рәвешкә кереп баралар иде. Мутация дигәне, бәлки, шулдыр,

бәлки, ул шулай төрле якка эшлидер? Югыйсә Чиләбе, Иртәш, Сөнкүлләрдә, махсус больницалар ачып, бу авыруларны шулхәтле нык өйрәнмәсләр иде.

Таһирҗан бабай яшәрүенә бара, ә аның туганнан туганы, ягъни Гөлҗиһанның әтисе, күзгә күренеп бетеренә. Бу кайтуында Гөлҗиһан аның шактый сулуын күрде. Әтисе инде аякларының калган өлеше сызлавыннан да зарлана, аларны кая куярга белми. Ул Гөлҗиһан алып кайткан көчле даруларга да ияләнгән бугай инде, аларны күпме эчсә дә, авыртуы басылмый. Газаплануларын сиздермәс өчен, ул, таягына таянып, аякларын чак өстерәп, бакча ягына чыгып китә һәм шунда озак кына утырып керә. Риза булса, ул аны, яңадан Чиләбе больницасына алып китеп, тагы операциягә салып карар иде, әмма әтисе риза түгел. Аның, ит бүкәненә әйләнеп, кеше күзенә карап утырасы килми шул. Шуңа күрә бик авыртса да түзә, өстерәлеп булса да йөри, үз көнен үзе күрә иде.

Бүген дә ул Гөлҗиһан белән Фәргатьнең балаларын күтәреп кайтып керүләренә сөенеченнән нишләргә белмәде. Ул инде оныкларын күрмичә үлеп китәрмен дип курыккан иде. Аллаһы Тәгалә аңа бу бәхетне дә күрсәтте. Ул хәтта үзенең сызлануларын да онытып җибәрде, кайтканнан бирле, оныклары белән мәш килә. Ә алар шундый матурлар, тереләр, сау-тазалар, әйтерсең Караболакны кырган афәт бу сабыйларны читләтеп үткән. Нәбиулла аларның телсез-чукрак икәнлекләрен белмәде, әле телләре ачылмаган балаларның нинди буласын каян беләсең? Ә Гөлҗиһан белән Фәргать беркемгә берни әйтмәделәр, алар үзләре дә әле могҗиза көткәндәй нидер өмет итәләр иде...

Ул арада Таһирҗан карт зур эшкә — балаларга исем куярга әзерләнеп беткән иде инде. Игезәкләрне ак якка, кабарып торган чиккән мендәрләр өстенә китереп салдылар. Тәрәзәдән кергән август кояшы сабыйларның йөзен иркәләде, яшькелт күзләрендә чагылды, үзенчә җылытырга, назлап калырга ашыкты. Таһирҗан карт шаулатып азан әйтте, дога кылды, камәт төшерде, шуннан соң сабыйларның икесенең дә ике колагына берәм-берәм исемнәрен кычкырып чыкты: «Гадел... Гадел... Гадилә... Гадилә». Игезәкләр үзләренә таба иелеп, нидер эшләгән ак бабайның сакалына үрелделәр, нидер әйтергә теләп гөрләделәр, елмаештылар. Моны күргәч, Гөлҗиһанның күңеле урыныннан купты. «Әллә ишетәләрме икән соң, Ходаем?! — дип уйлады ул, балаларына карап. — Күр, ничек куанышалар бит! Үз исемнәрен булса да ишетергә, белергә тиеш бит инде алар...»

Балаларның ишетмәүләрен Таһирҗан карт та белми иде, белсә дә, ул, йоласына туры китереп, нәкъ шулай исем кушар

иде. Ул белгәннән бирле Караболакта аның тәртибе шундый инде. Элек әле, исем куйдырганда, зурлап бәби туйлары үткәрәләр иде, һәркем бала туган йортка ризык-күчтәнәч белән килә иде. Бер яктан — советлар, икенче яктан моңарчы күрелмәгән чир-зәхмәт авыл халкын тәмам сындырды, халыкның гадәт-йолалары онытыла башлады. Әле ярый Гөлҗиһан, боларны искә төшереп, балаларын күтәреп кайткан. Югыйсә Аллаһ каршына нинди исем белән барырлар иде бу сабыйлар? Аларга дигән догалар кем исеменә укылыр иде?

Шуларны уйлап, Таһирҗан карт бөтен шартын китереп дога кыла башлады. Өйдә булган бар кеше — әби-бабайлар, ата-аналар, туганнар, кулларын күтәреп, аңа кушылып дога кылдылар, эчләреннән генә «Амин» дип тордылар...

— И Раббым, бу балалар ислам динен куәтләсен, көчәйтсен иде, — дип дога кылды Таһирҗан карт, таралып яткан сабыйларга карап. — Ата-аналарына карата игелекле, миһербанлы булсыннар иде. Бу балаларны ата-аналарына тигезлектә үстерергә насыйп булсын иде. Халкыбыз, милләтебез өчен файдалы кешеләр булып үсеп җитсеннәр иде... Амин.

— Сау-сәламәт булып үссеннәр иде, — дип, үзеннән өстәп куйды Гөлҗиһан.

Бар нәсел шушы сүзләргә кул күтәреп дога кылды. Шулай бөтен шартларын китереп, Караболакча исем кушканнан соң, кечкенә генә мәҗлес тә үткәреп алдылар. Элеккечә үк булмаса да, туган-тумача, күрше-күлән һәрберсе ризык күтәреп кергән, кем бәлеш, кем чәкчәк, кем паштет пешергән. Бавырсак, каклаган каз күтәреп килүчеләр дә бар. Гөлҗиһан белән Фәргать үзләре дә Иртәштән тәмле-томлыны күп төяп кайтканнар иде, өстәл өсте ризык белән тулды.

— Киң ризыклы булсыннар, — диде Ярулла карт, яраткан оныгының балаларына карап.

— Хәләл ризыклы булсыннар, — дип өстәде Нурҗамал карчык.

— Мөэмин-мөселман булып яшәсеннәр, ислам динен куәтләсеннәр, — диде Таһирҗан карт.

— Сау-сәламәт булсыннар, чир-зәхмәтләргә бирешмәсеннәр, — диде Нәбиулла карттайлары.

— Бәхетле булсыннар, үз тиңнәрен тапсыннар, — диде Хәбирә картнәйләре.

Гөлҗиһан белән Фәргать, бу изге теләкләрнең барысына да җаннары-тәннәре белән кушылып, «Амин» дип тордылар. Бу аларның балаларына ата-бабалары тарафыннан бирелгән фатиха иде. Балалар ишетәләрме моны, юкмы, аңлыйлармы, юкмы, бу теләк-догалар инде күкләргә киткән, тәкъдир китапларына теркәлеп куелган иде. Атом казаннарында

кайный-кайный, Караболак туфрагында Алып Ханнар нәселенең яңа буыны калкып килә иде. Ул яшәр өчен туа, яшәр өчен дөньяга килә иде.

Оныклары өчен иң нык сөенүче, мөгаен, Нәбиулла булгандыр. Ул берара үзенең авыртуларын да онытып торган кебек булды. Әмма мәҗлес бетәр-бетмәс, сызлануга түзә алмыйча, тагы бакча ягына чыгып китте. Бер аягында авырту шулхәтле көчле иде, әйтерсең сөякнең эченнән җелеген суырталар. Аны шулай коймага капланып, авыр ыңгырашып торган вакытында кызы Гөлҗиһан килеп тапты. Ул шунда ук әтисенең хәлен аңлады, аны тиз генә карттайларының буш йортына алып кереп салды, үзе исә әниләренә кереп, укол әзерли башлады. Фәргать белән икесенең дә хәле авыр булгач, ул һәрвакыт үзе белән бөтен дару-шприцларын йөртә, кирәк тапса, кан тамырына да укол ясый. Әтисенең кан тамырларына да ул иң көчле даруларны җибәрде, вакытлыча булса да, көчле авыртуны юкка чыгарды. Әмма бу җиңеләю вакытлыча гына иде, әтисен монда бу хәлдә калдырырга ярамый иде.

Күрше авылдагы совхоз директорының машинасын сорап торып, Гөлҗиһан әтисен тагы Чиләбегә алып барып кайтырга булды. Әмма аңа көнендә әйләнеп кайтырга кирәк иде, чөнки машина да шулай гына бирелгән, имчәк балаларны да озакка калдырып булмый. Балаларны әнисенә калдырып, Гөлҗиһан таң белән юлга кузгалды. Теле белән «барып кына кайтабыз» дисә дә, күңеле белән ул әтисенең кире кайтуы алай тиз булмасын аңлый иде. Шуңа күрә больница өчен бөтен кирәк-ярагын алды. Әмма теге вакыттагы кебек авыр вакытта әтисе янында була алмаячагы өчен ул ут йотты, чөнки ул имчәк балаларына бәйләп куелган иде.

Гөлҗиһан белеп борчылган икән: әтисенең бер аягында тиздән югары черү башланган, ашыгыч рәвештә кисеп ташламасаң, бөтен тәнгә таралырга мөмкин. Бу исә үлем дигән сүз. Тиздән икенче аягында да шул хәл башланырга мөмкин, шуңа күрә, анысын да кисеп ташласаң, ышанычлырак булачак икән. Аякларны тиздән кисү бер нәрсә, ә инде бот төбеннән кисеп ташлау — тере гарипкә, ит кисәгенә әйләнү дигән сүз. Боларны белгәч, Гөлҗиһан тирән кайгыга төште. Табиблар белән тагы бер утырып киңәшкәннән соң, хәзергә бер аягын гына бот төбеннән кисеп торырга булдылар. Икенчесе яртылаш кына булса да, ул аның белән таяк ярдәмендә йөри алачак иде.

Нәбиулланы элек яткан палатасына алып кереп салдылар, операциягә әзерли башладылар. Ул бу юлы элеккеге кебек тәвәккәл, тыныч түгел иде, гел боегып, күңелсезләнеп калган. Авыртуына түзә алмаганга, ул инде нәрсә эшләтсә-

ләр дә риза иде. Сугышлардан исән кайткан, авылда ничә еллар ут уйнатып эшләп йөргән, төпкә җигелеп дөнья тарткан, балалар үстергән әзмәвердәй ир-ат, язмышы белән килешеп, үз ихтыяры белән пычак астына кереп бара иде.

Күкрәкләре таш булып каткан, инде сөте саркып ага башлаган Гөлҗиһан, әтисенең күзләренә карый алмыйча, кире кайтырга әзерләнә башлады. Аның йөрәге үксеп-үксеп елый иде. Караболакта аны ике имчәк баласы, сукыр ире көтә, ә монда үлем күзенә карап әтисе ята. Әмма, ни генә булса да, аны биредә берьялгызын калдырырга ярамый, бигрәк тә операциядән соң. Аңа ярдәм һәм җан җылысы кирәк булачак. Авылдагы энеләре үзләре авыру, аларны монда ярдәмгә китерүдән бер мәгънә дә юк. Әнисе дә соңгы вакытта гел сыкранып, сызланып йөри, аның үзенә ярдәм кирәк. Гөлҗиһан да балаларга бәйләп куелган, ичмасам, ими иммәсәләр дә, бу хәтле булмас иде, ә хәзер ул аларны бер көнгә дә калдырып китә алмый. Балалар да ач, үзе дә күкрәкләреннән ташып аккан сөтен нишләтергә белми. Анда бит әле дөм сукыр ире дә бар, ул үзе олы бала кебек, һәрвакыт игътибар һәм тәрбия кирәк. Югыйсә аның тагы шул рестораннар ягына борылуы бар...

— Әти, мин Караболакка кайтып киләм, — диде ул, аны урнаштырып бетергәч. — Мин ничек тә яңадан килергә тырышырмын. Нәрсә булса да уйлап табарбыз, Алла теләсә. Син борчылма, әти, барысы да сөйләшенгән, барысы да яхшы булачак.

Нәбиулла аны тын гына озатып калды...

Тимер аякларын салып куйгач, аның гәүдәсе кыскарып, үсмер малайларныкы кебек кенә калган иде. Йөзен исә газап җыерчыклары каплаган. Бу күренеш Гөлҗиһанга гарип балалар йортын хәтерләтте. Бу каргалган җирдә балалар белән картларның язмышлары уртак иде.

Гөлҗиһан килгән машинасы белән кичкә таба Караболакка кайтып китте. Ул нәрсә эшләсен әле үзе дә белми иде. Иртәгә әтисенә операция ясалачак, бу хәлдә аның ялгызын гына калдырырга ярамый. Нишләргә? Бәлки, балаларны алып чыгып китәргәдер Чиләбегә? Аларны анда кая куяр?

Аңа ярдәмгә ире Фәргать килде.

— Бабайны бу хәлдә ялгыз калдырырга ярамый, — диде ул, җитди бер карарга килеп. — Без бергә китик Чиләбегә, Гөлҗиһан. Мин берәрсендә балаларны карап торырмын, син бабай янында больницада булырсың. Балаларны имезергә кайтып йөрерсең. Операция вакытында булса да аның янында булырга кирәк.

Өйдәгеләр белән җыелып киңәшкәннән соң, шулай килештеләр.

Чиләбедә Таифәттәйнең кызы белән кияве яши — шулар-

да торып торырга булдылар. Икенче көнне таң белән, Чиләбе — Сверловск олы юлына төялеп чыгып, беренче очраган машинага утырып киттеләр. Алланың рәхмәте, бу татар кешесе аларны Таифәттәйләрнең кызларына хәтле илтеп куйды. Бәхетләренә, өйдә балалары бар иде, алар Фәргать белән Гөлҗиһанны танып, шунда ук ачып керттеләр. Ирен һәм балаларын шунда урнаштырып калдыргач, Гөлҗиһан, такси алып, туп-туры больницага китте. Әтисенә операция башланганчы, ул анда барып җиткән иде инде. Ак халат киеп үз янында басып торган кызын күргәч, Нәбиулла үз күзләренә ышанмады, аннан бар газапларын онытып елмаеп җибәрде. Гөлҗиһан килмичә каламы соң?! Җиде кат җир астыннан юлын табачак ул әйткәнен эшләү өчен, түбәдән төшәчәк, әмма үз дигәнен булдырачак. Ата кеше аның барыбер килеп җитәсен, иң авыр вакытларда янәшәсендә булачагын белә иде. Аңа җиңел булып китте, ул Гөлҗиһанның кулларыннан кысты, шул хәлдә күзләрен йомды. Үз язмышын кабул итәргә тыныч күңел белән әзерләнде, чөнки ул ялгыз түгел, аның янында фәрештәгә тиң изге күңелле кызы басып тора иде...

Алланың рәхмәте, бу операция дә уңышлы үтте, авыру тәнгә таралып өлгергәнче, бер аякны бот төбеннән кисеп ташладылар. Икенчесенә хәзергә кагылмаска булдылар, чөнки Гөлҗиһан шулай теләде. Ул әтисенең тере гарипкә, урын өстендә яткан ит бүкәненә әйләнүен теләмәде. Күпме гомере калса да, сыңар ярты аягында йөреп булса да уздырсын. Сансыз, кирәксез кешегә әйләнмәсен. Тимер аякларда булса да Караболак урамнарында йөри алсын.

Операциядән соң да Гөлҗиһан әтисе яныннан китмәде, көндез аны саклады, төнгә балалары янына кайтып егылды. Фәргатьнең эшенә шалтыратып, ике атнага түләүсез ял алдылар, ә Гөлҗиһан болай да декрет ялында иде. Аларның Чиләбедә икәнлекләрен белеп, больницага Галия апалары да килеп китте. Ул инде эшләми икән, шактый бетеренгән, авыру аны аяктан егып килгәнлеге күренә. Гөлҗиһан бик чакыргач, ул Фәргать янына да килеп китте, аларның балаларын күреп, бик куанды. Әмма Гөлҗиһан аңа да балаларының телсез-чукрак булып тууларын әйтә алмады, чөнки Галия апасы бу хакта алдан ук кисәткән иде бит. Тик Галия апасы белән дә соңгы тапкыр очрашуын, ул китеп бераз вакыт узуга аның дөнья белән хушлашасын Гөлҗиһан белми иде әле.

Әтисе тәмам тернәкләнеп терелә башлагач кына, Гөлҗиһан Иртәшкә кайтырга җыенды. Элеккеге кебек, аңа алмашка авылдан Таһирҗан бабай килеп җитте, ул үзенә иптәшкә Гөлҗиһанның энеләрен дә алган иде. Әтисен шулар кулына ышанып тапшыргач кына, Гөлҗиһаннар юлга кузгалды. Бу

юлы да больницада Караболак халкы шактый ята иде, алар, берәм-берәм палаталарыннан чыгып, Гөлҗиһанны моңсу гына озатып калдылар. Һәм аларның күбесен Гөлҗиһан инде башка беркайчан да күрмәде, үлгән хәбәрләрен генә ишетте. Ул арада Караболакта сигезенче зират ачылган иде инде.

Бу юлы, Чиләбе больницасында әтисен караган арада, Гөлҗиһан авылдашларының авырулары белән дә ныграк кызыксынды. Кайсы үзендә йөрәк чире, кайсы кан басымы диде, гомуми чир дип ятучылар да байтак иде, әмма алар бу авыруларының сәбәбен дә, ни белән бетәсен дә белмиләр иде. Ахрысы, алар берсе дә дөресен белмиләр иде. Һәм Гөлҗиһан, тәвәккәлләп, табиблардан авылдашларының авыру тарихларын күрсәтүләрен сорады. Биредә аны күптән белсәләр дә, Иртәш больницасының өлкән шәфкать туташы буларак, хөрмәт итсәләр дә, аңа башкаларның авыру тарихларын бирергә ашыкмадылар. Алар исәбенчә, һәр больницаның үз тәртибе, үз сере бар, һәм аны теләсә ничек бозарга ярамый икән. Гөлҗиһанның: «Караболак халкы нигә бу хәтле күп авырый һәм үлә соң?» — дигән соравы да, нигездә, җавапсыз калды. Биредә һаман элеккечә авыл халкының үзен гаеплиләр иде әле, имеш, эчәләр, начар туклананалар, дөрес яшәмиләр, туганнар белән өйләнешәләр. Биредә әле бернәрсә дә үзгәрмәгән иде. Бу ялганны Гөлҗиһан инде дистә еллар ишетеп килә һәм моның дөрес түгел икәнлеген белә иде.

Алайса, нәрсәдә соң эш? Әтисе һәм ире әйткәнчә, бөтен хикмәт Иртәштәме? Атомдамы? Шулай икән, нигә табиблар, галимнәр, ил җитәкчеләре бу хакта чаң какмыйлар, халыкка дөресен әйтмиләр, кешеләрне бу афәттән коткару өчен ашыгыч чаралар күрмиләр? Сугыш вакытында, хәтта ачлык елларында да авылда бу хәтле күп кеше үлмәгән, ә хәзер исә яшьләр кырыла, балалар үлә, Караболак тулы гарип-гораба, тиленләр. Гөлҗиһанның үз өендә дә өч гарип, үзе дә көнетөне дару өстендә утыра. Әтисе ике аяксыз, чират кулларга да җитәргә мөмкин, чөнки бу шундый авыру. Әнисе, энеләре гел авырып тора. Алар нәселендә эчү юк бит, ашаулары да яхшы, гаиләдә тәртип. Нинди үләт шулай кыра соң Караболакны, Гөлҗиһаннар нәселен, Алып татарлар токымын?

Гөлҗиһан Иртәшкә кайтып озак та тормады, авылда бербер артлы Ярулла карт белән Нурҗамал карчык үлеп киттеләр. Гөлҗиһаннар тагы ашыгып, төялешеп Караболакка кайтып җиттеләр. Чиләбе больницасыннан Нәбиулланы да чыгарганнар иде инде, ул, таякка таянып булса да, ата-анасын соңгы юлга үзе озатты. Карт белән карчык туксанга җитеп, авырмыйча тыныч кына үлеп китсәләр дә, Гөлҗиһан өчен бу бик зур югалту булды. Чөнки аның бөтен бала чагы картнәе белән карттае янында үтте, ул ике йортның кадерлесе булып

үсте һәм гомер буе шулай булып калды. Аның бөтен сере, шатлык-кайгылары алар белән уртак иде. Гөлҗиһанның тормышында бу беренче шундый зур югалту булды. Ул әбибабасына игезәк сабыйларын алып кайтып күрсәтүенә сөенде, аларның дога-фатихасын алып кала алуына шатланды. Хәзер исә алар Гөлҗиһаннан дога көтеп яталар иде.

Ярулла карт белән Нурҗамал карчыкны бөтен Караболак зурлап озатты. Аларга Таһирҗан карт, үзе җеназа укып, Караболакның сигезенче зиратына җирләде. Алып Ханнар нәселендә иң өлкән кеше булып хәзер ул калды. Караболакта да ул иң карт кешеләрнең берсе иде.

## Бишенче бүлек

Тормыш шулай Караболакта да, Иртәштә дә үз җаена дәвам итте. Кешеләр үлә торды, туа торды, ни генә булса да, тормыш тукталмады.

Игезәкләрдән соң Гөлҗиһан тагы бер бала тапты, әмма ул үле туды. Кыз бала иде, Миләүшә дип исем кушып, Караболак зиратына, әби-бабалары янына алып кайтып күмделәр... Табиблар әйткән дөрескә чыкты — игезәкләрнең теле ачылмады. Алар гомергә телсез-чукрак булып калдылар. Аларның шундый булуларына да ата-анасы индеияләште, ә нишлисең? Хәзер шушы хәлдә яшәргә өйрәнергә кирәк инде, аларны да шуңа өйрәтергә. Иртәштә мондый балалар бик күп иде, шуңа күрә алар өчен махсус балалар бакчалары, интернат-мәктәпләр оештырылды. Бу Гөлҗиһан өчен дә бик кулай булып чыкты, ни әйтсәң дә, анда балаларны укыргаязарга, үзләренчә бармаклар белән сөйләшергә, аралашырга өйрәтәләр. Шушы гарипләргә дә белем һәм һөнәр бирергә тырышалар, чөнки нинди генә булсалар да, киләчәк шулар кулына калырга тиеш иде.

Ни гаҗәп, Фәргать игезәкләрне үзенчә танырга өйрәнде, аны инде балалардан аерып алып булмый иде. Алар да әтиләренең ике аягына килеп ябышып, аңа тотынып йөрергә, яшәргә өйрәнделәр, Гөлҗиһанга караганда күбрәк аңа сырыштылар. Фәргать, балалар ишетсәләр дә, ишетмәсәләр дә, алар белән туктаусыз сөйләште, аларга иң матур, иң назлы сүзләрне әйтте. Читтән карап торышка, җан тетрәткеч күренеш иде бу: сукыр ата һәм телсез-чукрак балалар бер-берләренә яратуларын аңлаталар. Атаның аларны беркайчан күргәне, тавышларын ишеткәне юк, балалары аны күрә, әмма ни әйткәнен ишетмиләр, аңламыйлар. Фәргать аларны йөрәге белән күрә, җаны-тәне белән тоя, ә балалар нәни иреннәре белән әтиләренең битенә сөю сүзләре язалар.

Игезәкләр мәктәпкә барган елны Гөлҗиһан, тәвәккәлләп, тагы бер бала тапты. Монысы туганда ук баһадир кыяфәтле, биш кило ярымлы гаҗәп таза бер ир бала иде... Аны карарга бөтен больница җыелды, чөнки Иртәштә әле мондый зур баланың туганы юк иде. Инде үзе дә утызның теге ягында булган Гөлҗиһанга бу баланы табу шактый авыр булды, әмма ул ярып алырга ризалыгын бирмәде, баласына зыян килер дип курыкты. Бала бу якты дөньяга үз көче белән килсен өчен, алар аның белән икәүләп көрәштеләр. Ул көнне Фәргать игезәкләр белән көне буе больница тәрәзәсе каршыннан китмәде. Баһадир кебек зур гәүдәле малайны тәрәзәгә күтәреп күрсәткәч, ул үз күзләре белән күргәндәй куанды, игезәкләр исә шатлыкларыннан үрле-кырлы сикерделәр, кулларын болгап, нидер аңлатырга тырыштылар. Бу мизгелләрдә Гөлҗиһаннан бәхетле кеше юк иде — кулында саутаза улы, урамда яраткан ире, туп кебек балалары. Алар хәзер биш җан. Әмма иң сокландырганы, иң шаккатырганы — менә бу яңа туган сабый... Ул елый башласа, аның тавышыннан бөтен больница яңгырап тора. Имә башласа, анасының күкрәгендә сөт җитми. Берәр нәрсәне кысып тотса, кулыннан каерып алып булмый. Баһадир, чын мәгънәсендә баһадир бала иде бу...

Малайның исемен дә Баһадур дип куштылар.

Фәргатьнең Зөлкарнәйләр нәселендә шул исемдәге бер баһадир кеше булган икән. Ул галәмәт зур гәүдәле, күкрәп торган тавышлы, гаять укымышлы әүлия кеше булган дип сөйлиләр. Иртәштә бик сирәк була торган хәл — баланың бөтен җире дә сәламәт иде. Әтисенеке кебек зур коңгырт күзләре дә күрә, тавышны да яхшы ишетә, димәк, теле дә ачылачак. Дүрт саны исән, анализлары да яхшы. Моңа сөенеп бетә алмадылар, укыган догалары, теләгән теләкләре кабул булганга чын күңелдән ышандылар. Фәргать белән Гөлҗиһан, бу бала тугач, үзләре дә терелеп, тернәкләнеп киткән кебек булдылар, өйдә шатлык артты, мәшәкать артты, бала тавышы артты.

Баһадир йортка, гаиләгә чын мәгънәсендә бәрәкәт тә алып килде...

Ул тугач, әле чиратлары җитеп бетмәсә дә, дүрт инвалид торганны һәм яшь бала туганны исәпкә алып, исполкомнан өч бүлмәле өр-яңа фатир бирделәр. Дүртәүләп бер кечкенә бүлмәдә яшәп ятканнан соң, бу фатир аларга дала кебек тоелды. Игезәкләр, бүлмәдән бүлмәгә кереп-чыгып йөри-йөри, адашып беттеләр. Ленинград проекты белән эшләнгән киң озын коридорлар, бүлмәләрнең буеннан-буена сузылган балкон-лоджиялар, аерым бүлмә хәтле әйбер кую урыннары алар өчен могҗиза булып тоелды. Тәрәзәдән исә диңгез кебек Ир-

тәш күле күренеп тора. Ә еракта, күл аръягында, атом комбинатының кара торбалары күренә. Алар әйтерсең лә зәңгәр күл аша бу гаилә бәхетенә кара йодрыкларын болгыйлар иде...

Шулай итеп, Гөлҗиһан белән Фәргать Иртәштә яңа тормышларын башлап җибәрделәр. Инде моннан каядыр китү турында сүз бармый, алар тамырларын монда җибәргәннәр иде.

Алар атом казаны өстендә оя корган тау бөркетләрен хәтерләтәләр иде...

Баһадурны да Караболакка исем куйдырырга алып кайттылар. Могҗизага тиң бу баланы карарга бөтен авыл җыелды, чөнки Караболакта күптән инде мондый сәламәт, таза баланың туганы юк иде. Моны күреп, авыл халкында өмет уянды, элеккеге таза-сау вакытлары исләренә төште. Хәтта үләргә яткан Рәшидә дә, урыныннан торып, классташ кызының баһадир улын күрергә килгән иде. Әмма Баһадурны күтәрергә аның көче җитмәде, ул тәмам кипкән-корыган, җил иссә дә аварга тора иде. Гөлҗиһан аңа тагы күп итеп дарулар бирде, дөнья кадәр кием-салым тоттырды, Рәшидә, шуңа балалар кебек куанып, өйләренә кайтып китте.

Баһадур өчен иң нык куанганы бабасы Нәбиулла булды. Гөлҗиһанның беренче балалары телсез-чукрак тугач, ул кызын бик кызганган иде. Чөнки, аның уйлавынча, шушы хәтле уңган-булган, шушы хәтле чибәр Гөлҗиһаннан бары тик үзе кебек тере балалар гына туарга тиеш иде. Һәм менә Аллаһы Тәгалә аларның теләк-догаларын ишетте, ахры, нәселгә баһадир бала бирде. Бөтен авылга, юк, бөтен тирә-якка дан бала! Алып Ханнар нәселен дәвам итүче ир бала! Хәзер Нәбиулла тынычлап теге дөньяга да китә ала инде. Ул сәламәт оныгын үз күзләре белән күрде, үз кулларына алып сөйде, үз фатихасын бирде.

Ике аяксыз калгач та, Нәбиулла әле яшәргә тырышты, шушы хәлдә дә йортта төп кеше булды, үз тормышын үзе тартты. Ул авырудан башлары чыкмаган малайларын аякка бастырды, укытты, кеше итте. Алар, әтиләре кебек, каннарында атом тамгасы йөртсәләр дә, үлем көтеп ятмадылар, берсе — юрист, икенчесе югары белемле хәрби булды, Караболактан читкә китеп, үз көннәрен үзләре күрә башладылар. Алардан калган бушлыкны Гөлҗиһанның балалары тутырды, Нәбиулла соңгы йөрәк җылысын оныгы Баһадурга бирде.

Яман чир дә тик ятмады, Нәбиулланың бөтен тәненә таралды. Инде кулларны кистерергә чират җитте. Монысына инде Нәбиулла риза булмады. Ике кулсыз, ике аяксыз хәлдә кеше өстендә йөк булып ятасы килмәде аның. Ул инде яшәсен яшәде, күрәсен күрде, инде кеше хәлендә дөнья белән хушлашса да була иде.

Һәм әле алтмыш биш яше дә тулмаган килеш, Караболакның Алып Ханнар нәселеннән Нәбиулла яткан җиреннән тормады. Ул, җиңел үлем белән, йоклаган җиреннән үлеп китте.

Аны соңгы юлга озатырга бөтен авыл җыелды. Иртәштән төялеп Гөлҗиһаннар да кайтып төштеләр.

Таһирҗан карт, үзе җеназа укып, энесе Нәбиулланы Караболакның тугызынчы яңа зиратына күмде.

Иртәштә атом шартлавын үз күзләре белән күргән, утыз ел буе әҗәлнең кара тамгасын канында, тәнендә йөрткән тагы бер татар ире бу дөньядан китеп барды. Әмма аның атом афәтеннән үлүен әле авылда һаман белмиләр иде, ә белүчеләр дәшми, чөнки бу татарлар алар өчен тәҗрибә үткәрергә генә кирәк иде.

Иртәш, Караболак буйларында тереләр һәм үлеләр өстендә атом тәҗрибәсе уздыру дәвам итте... Һәм шушыларның барысына да чик куярга теләгәндәй, 1986 елның 26 апрелендә Чернобыльдә атом фаҗигасе булды. Башта аның аянычлы нәтиҗәләрен халыктан яшерергә тырышсалар да, моны яшереп калу мөмкин түгел иде. Үзенең меңләгән гарипләре, авырулары, мутантлары, коточкыч чирләре белән ул дөньяга бәреп чыкты. Иртәш Чернобыльне тудырды, Чернобыль исә Иртәшне ачты. Ягъни Иртәштә 1957 елгы атом шартлавын яшерү Чернобыль фаҗигасенә сәбәпче булды.

Чернобыль фаҗигасеннән соң Иртәштәге хәлләр дә ачыла башлады...

Чернобыль авариясе бөтен дөньяга хәбәрдарлык бомбасы булып шартлады.

Ниһаять, кешеләр атомның һәм радиациянең нәрсә икәнен аңлый башладылар — фаҗига үзе боларны ачып күрсәтте. Боларның нәтиҗәсе коточкыч иде. Ниһаять, газета-журналларда бу хакта язмалар күренә башлады, урамнарга экологлар, хокук яклаучылар бәреп чыкты, сәясәтчеләрнең теленә «атом», «радиация» сүзләре менде.

Дөньяны тетрәткән бу хәбәрләр Иртәшкә дә килеп җитте.

Чернобыль авариясеннән соң авырган кешеләрнең бөтен билгеләрен үзләрендә дә күреп, Гөлҗиһан тынсыз калды. Бөтен Караболак нәкъ Чернобыль фаҗигасен кичергән кешеләр кебек авырый иде. Нәкъ шундый авырулардан үлә иде. Әмма Чернобыльдә яман шешнең котыруын, кешеләрнең аягүрә череп үлүләрен нурланыш, радиация белән бәйләсәләр, Караболакта шушындый ук хәлләрне кешеләрнең үзләреннән күрәләр иде. Имеш, дөрес яшәмиләр, шуңа күрә «гомуми авыру»дан үләләр. Моның алай түгел икәнлеген күптән белсә дә, Гөлҗиһанның кемнедер гаепләргә дәлилләре юк иде. Чернобыль аңа ул дәлилне бирде. Һәм Гөлҗи-

һанның күзләреннән калын пәрдә төшкән кебек булды — аның авылдашлары Иртәштәге «Маяк» комбинаты тараткан радиация корбаннары иде. Ул үзе дә, ире, балалары, ата-анасы, туганнары — барысы да атом радиациясе корбаннары иде. Фәргатьнең сукырлыгы да, игезәк балаларының телсез-чукрак булып туулары да, Гөлҗиһандагы кан авыруы, яман чир дә — барысы да шуннан иде. Караболак зиратына күчеп беткән бөтен классташлары да радиация корбаннары иде.

Гөлҗиһан бер сорауга барыбер җавап таба алмады.

Бу чыннан да шулай икән, нигә халыкка башта ук дөресен әйтмәгәннәр, аны бу афәттән коткарырга тырышмаганнар? Бу хакта белүчеләр булгандыр бит инде? Халык авырган саен, аның үзен гаепләргә тырыштылар, күрә торып, аны радиацияле урында яшәтеп калдырганнар булып чыга түгелме соң? Бу уеннан Гөлҗиһан калтырап китте, үзенең һәм авылдашларының соңгы утыз елда нинди шартларда яшәвен күз алдына китерде. Тукта, теге вакытта, Иртәштәге шартлаудан соң, Караболакны да күчерергә йөрделәр түгелме соң? Димәк, хөкүмәт аның радиациядән зарар күрүен белгән, әмма авылны башка урынга күчермәгән? Нигә?

Гөлҗиһан бу сорауларына җавап таба алмады...

Бу хакта ире белән дә киңәшеп карарга булды. Иртәштә атом бомбасы ясалганын ишетеп белсә дә, аның кеше өчен бу хәтле зарарлы икәнлеген аңлап бетермәгән икән Гөлҗиһан. Чернобыль аның күзләрен ачты. Иртәш аның йөрәгенә шом сала башлады. Алар үзләренең тормышларын атом казаны өстенә, радиация болыты эченә корганнар түгелме соң? Болай булгач, бөтен шәһәр атом бомбасы өстендә, атом калдыклары арасында утыра түгелме соң? Шуларны белә торып, алга таба монда ничек яшәргә?

— Син сораганнарның кайберсен мин солдатта хезмәт иткәндә үк белә идем инде, — диде Фәргать, хатынын гаҗәпкә калдырып. — Без биредә күп яшерен объектларны саклыйдык бит. Аларда авария булса, чистартырга да безне җибәрәләр иде. Әмма болар барысы да бик каты хәрби сер булып тора иде. Алар турында сорарга да, сөйләшергә дә ярамый иде. Мин үземнең нидән гарип калганымны бик яхшы беләм. Игезәкләрнең нидән шундый булып туулары да беләм. Без монда, Чернобыльдәге кебек, атом радиациясе эчендә яшибез.

— Әмма мин Иртәшкә соң килдем бит, тик барыбер шундый ук чир белән авырыйм. Бөтен Караболакта шушы хәл.

— Иртәш белән Караболак арасы ерак түгел бит. Монда ни булса, анда да шул ук хәл. Хәтерлисеңме, теге вакытта, без әти белән Караболакка килгәч, Иртәш ягында көчле шарт-

лау булган иде? Сине кырдан ат арбасына салып алып кайтканнар иде? Син ут булып яна идең, яныңа якын килерлек түгел иде. Без икенче көнне Миасска кайтып киттек, аннан мин сине әтине күмәргә кайтканда гына күрдем. Менә шул илле җиденче елгы шартлау вакытында ук без барыбыз да шушы чирне эләктергәнбез инде. Шул исәптән әти белән мин дә. Әти дә кан косып үлде бит, анда рак булуын үлгәч кенә әйттеләр, ярып карагач кына белделәр. Әти сезгә барган көзне көчле радиация алган булган.

— Димәк, бөтен Караболак халкы да шул вакытта ук радиация алган булып чыга бит! — диде Гөлҗиһан, куркыныч ачыш ясап. — Шуңа күрә анда үлем күп, гарипләр күп. Моны белүчеләр булгандыр бит инде, Фәргать?! Белә торып, халыкны ничек шундый җирдә калдырдылар икән? Бу бит коточкыч, бу бит җинаять!..

Гөлҗиһанның үз сүзләренә үзе ышанасы килмәде. Дөрес, ул элек тә Караболак белән нидер булганын, бу үлем-җитемнәрнең Иртәш белән бәйләнгәнен сизенә иде. Чернобыль аның күзләрен ачты. Иртәштә дә, нәкъ Чернобыльдәге кебек, атом шартлавы булган бит. Бөтен тирә-якны сәгате-минуты белән радиация каплаган, Караболак та атом болыты астында калган. Аны юкка гына теге вакытта башка урынга күчерергә йөрмәделәр бит инде. Ә күчермәделәр. Димәк, аларны анда, белә торып, череп үләргә калдырганнар. Тәҗрибә, сынау өчен калдырганнар. Бу тәҗрибәнең нәтиҗәсе — Караболактагы сигез зират. Гөлҗиһан өендәге дүрт гарип... Ул хәтта улы Баһадурның да бу кадәр эре гәүдәле баһадир булып туууыннан бераз куркып калды. Чөнки медик буларак ул белә, гадәттә, матдә алмашыну дөрес булмаганда, канда шикәр күп булганда, шундый эре балалар туа. Бу чирләр барысы да Гөлҗиһанда бар, әгәр Баһадурда да шул хәл кабатланса?

— Хәзер ачыктан-ачык сөйләгән нәрсәләр теге заманда барысы да дәүләт сере иде бит, — дип, башлаган сүзгә йомгак ясап куйды Фәргать. — Атом бомбасы СССРның иң зур дәүләт сере иде, бу әле хәзер дә шулайрак. Игътибар итсәң, Иртәш бит әле һаман ябык, яшерен шәһәр, аның адресы да почта ящигы саны белән йөртелә. Перестройка килде дип, монда әллә нәрсә үзгәрмәде бит. Солдат вакытта кайбер өлешләрен күрдем мин ул җир астындагы атом шәһәренең. Анда чыпчык борын тыгарлык түгел. Җир астында Урал тауларына хәтле тимер юллар кера, бер якка — уран, икенче якка атом коралы ташыйлар. Анда очы-кырые күренмәгән заводлар, атом калдыклары белән тулган кургаш баклар, агу тулы җир асты күлләре, көне-төне үкереп эшләп торган атом реакторлары, яшерен бункерлар, күзәтү пунктлары, шәүлә кебек

кешеләр. Болар хакында беркайчан да халыкка әйтмәячәкләр, газеталарга да язмаячаклар. Шушы хәтле куәтле, бар дөньяны тетрәтеп торган атом индустриясе каршында радиациядән кырылып яткан бер татар авылы нәрсә ул? Безнең язмышлар нәрсә? Менә шуңа күрә Караболак халкына да берни әйтмәделәр һәм әйтмәячәкләр дә...

Ире белә, бу сөйләшүдән соң Гөлҗиһан шактый вакыт аңына килә алмыйча йөрде. Аның өчен хәзер барысы да ачык иде, ул үзен гомер буе газаплаган сорауларга җавап тапты. Әмма аннан кемгә нинди файда? Караболакның тилмереп үлгән кешеләренә ни файда? Һәр көн үлем көтеп яткан тереләргә ни файда? Иртәш атомы аркасында дөм сукыр калган Фәргатькә, телсез-чукрак ике баласына, үсмер чактан нурланыш алган Гөлҗиһанның үзенә ни файда боларны белүдән? Шушыларны белгәннән соң, бу илдә, бу кешеләр арасында, бөтен тирә-якны агулап яткан бу шәһәрдә ничек яшәргә? Атом комбинаты бүген дә бар көченә эшләп ята бит, димәк, ул эшләп торганда, Караболак халкын киләчәктә дә шундый ук газап көтә?! Ә халык бу турыда берни белми бит, аннан фаҗиганең сәбәпләрен яшерәләр. Халык шулай ук үзенең хокукларын да белми. Бер төймә даруга, аспиринга тилмереп, нидән чирләгәнен дә белмичә, үз илендә, үз өендә череп үлә. Сугыш та кирәкми. Димәк, аның балаларын, гаиләсен дә шундый ук язмыш көтә?

Бу көннәр, дөньяда барган бу үзгәрешләр, яңалык-хәбәрләр Гөлҗиһанның бөтен тормышын актарып ташлады. Ул дөньяга бөтенләй башка күз белән карый башлады. Караболак халкының бу бәхетсезлегә өчен кем гаепле? Ул шушы сорауга төгәл җавап табарга тиеш иде. Тапкан очракта, ул гаепле затлар җавап тотарга тиешләр иде. Башкача була алмый... Чөнки шушы илле җиденче елгы шартлаудан соң гына да Караболакта мең ярым кеше үлгән, боларның санын Таһирҗан бабай алып бара. Нидән үлгән алар, нигә үлгән? Гөлҗиһан иң беренче шушы сорауларга җавап табарга тиеш иде.

Ул инде теге вакытта ук Чиләбе ФИБыннан Караболак халкының авыру тарихларын, анализларын алырга тырышып караган иде, әмма аңа аны бирмәделәр. Хәзер заманнар үзгәреп, күп нәрсәләр ачылгач, билгеле булгач, Чиләбедә дә моннан олы сер ясап тормадылар, Гөлҗиһанга авылдашларының авыру тарихы белән танышып чыгарга рөхсәт иттеләр. Бу яшерен белешмәләр белән танышкач, ул телсез калды, биредә махсус хисапта торган меңнән артык авылдашының барысында да нурланыш һәм рак булганлыгын белде Гөлҗиһан. Аларның инде берсе дә бу дөньяда юк иде. Кулларында «гомуми авыру» дигән белешмә белән, дәүләт тара-

фыннан бернинди ярдәм күрмичә, алар инде үлеп беттеләр. Димәк, калганнарында шушы ук чир, әмма аларга һаман «гомуми авыру» дигән диагноз куюны дәвам итәләр. Нәтиҗәдә, ярдәм дә юк, ташламалар да юк, тиешле даруы, пенсиясе дә юк. Караболак халкының хәле нәкъ Чернобыльдәге кебек булса да, аларга дәүләт тарафыннан бернинди ярдәм күрсәтелми. Нишләргә, бу мәсьәләне кайда күтәреп карарга, кемгә әйтергә?

Беркөнне Гөлҗиһан эшли торган больницага җитмеш яшьләрендәге бер картны китерделәр. Аны заманында зур кеше булган диделәр, аның өчен аерым палата әзерләделәр. Больницаның өлкән шәфкать туташы буларак, Гөлҗиһан бу картка бөтен шартларын тудырырга тиеш иде. Биредә элек тә зур-зур түрәләр ятып чыкканга, Гөлҗиһан өчен мондый кешеләрне карау авыр эш түгел. Әмма авыруның үзен күргәч, ул сискәнеп китте — карт дөм сукыр иде. Һәм аның бөтенләй караучысы юк икән — хатыны үлгән, дауна чирле дивана улы Сөнкүл больницасында ята, диделәр. Үзенең дә ире шушындый хәлдә булгач, Гөлҗиһан бу картны бик кызганды, аны карау һәм дәвалауны иң югары дәрәҗәдә оештырды, аның белән кешечә сөйләшеп утырырга да мөмкинлек табарга тырышты.

Бу татар хатынының үзенә карата эчкерсез мөнәсәбәтен күргәч, сукыр карт та бераз эри, ачыла төште. Югыйсә башка шәфкать туташлары аның кырыслыгыннан, катылыгыннан зарланалар иде, ә Гөлҗиһан белән ул алай булмады. Үзенең гомерлек гадәте буенча, карт аның тормышы белән кызыксынды, кайсы яклардан икәнлеген, кемлеген сораштырды. Гөлҗиһан авызыннан Караболак сүзен ишеткәч, сукыр карт сискәнеп киткән кебек булды, аннан әкрен генә сорап куйды:

— Ул авылда кешеләр бармыни әле?

Аның бу соравыннан Гөлҗиһан тетрәп китте. Нигә алай сорый бу сукыр карт? Каян белә ул Караболакны?

— Нигә булмасын, авыл һаман яшәп ята, — диде ул, картның бу соравына гаҗәпләнеп. — Дөрес, кешеләр бик күп үлә. Авылда инде сигез зират тулды. Ә сез Караболакны каян беләсез?

Карт сукыр күзләре белән караңгы бушлыкка текәлде.

Аның күз алдына пычракка батып утырган зур татар авылы килде. 1947 елның көзе иде бу. Иртәштә зур эшләрнең әле башланган гына чагы. Тирә-юнь авыллардан ышанычсыз кешеләрне сөрергә кирәк. Бигрәк тә бөтен тирә-якка үзенең усаллыгы белән дан тоткан Татар Караболагы авылын ныклы күзәтүгә алырга. Биредән бөтен ышанычсызларны куып бетерергә һәм Иртәштәге атом комбинаты өчен

«Особоя зона» ясарга. Радиациянең тәэсирен берничә буын тере кешеләр өстендә өйрәнергә, аның өчен аларны бер урында туплап тотарга. НКВД табибларына даими рәвештә балаларның һәм олыларның каннарын алып, тикшереп торырга, мәетләрне яңадан казып алып, сөякләрен тикшерергә. Бериянең яшерен әмере шундый иде һәм ул ахыргача үтәлде. Ә анда әле барыбер кешеләр калган икән.

— Син ничәнче елгы буласың? — дип сорады карт Гөлҗиһаннан.

— Кырык алтынчы елның көзендә туган мин, — дип җавап бирде Гөлҗиһан. — Мин туганда әти Караболакта авыл советы председателе булган. Алып Ханнар нәселеннән әзмәвер Нәбиулла дип йөртәләр иде аны. Хәзер мәрхүм инде, урыны җәннәттә булсын.

Хәтерли, бик яхшы хәтерли сукыр карт бу әзмәвер татар ирен. Ул бөтен авылны аңа каршы күтәрә язды теге вакытта. Кем сәнәк, кем балта күтәреп урамга чыккан авыл ирләрен дә яхшы хәтерли ул. Бәхетенә, янында солдатлар күп иде, халыкка баш күтәрергә ирек бирмәделәр. Димәк, бу хатынның атасы шул бунтарь татар булган! Аны, әлбәттә, ул чакта ук бөтереп тыгып куярга була иде, яклаучылары табылды, имеш, сугыш батыры, инвалид кеше. Хәер, алар өчен ул авылда калу төрмәдә утырудан да начаррак булгандыр. Әнә, сигез зират тулды, ди бит, ул барганда, авыл башында бер генә зират бар иде. Теге бунтарь татар да шунда күчкән, югыйсә алар аның белән бер тирә иде бит.

Әйе, бу сукыр карт — КГБ генералы Ткаченко иде.

— Үзеңнең гаиләң бармы соң? — дип сорады ул Гөлҗиһаннан, нигәдер күбрәк белергә теләп.

— Бар, ирем адвокат булып эшли, өч балабыз бар, — дип җавап бирде Гөлҗиһан ачылып. — Бик әйбәт яшибез, Аллага шөкер.

— Ирең дә сезнең авылданмы?

— Әйе, Караболакныкы... Тик аларны кырык җиденче елда Миасска сөргән булганнар.

Карт чекист бу хәлләрне дә бик яхшы хәтерли.

Көзге карлы-бозлы юлда чегән кебек арбаларга төялеп Караболактан чыгып киткән татар гаиләләрен бүген дә хәтерли ул. Ак сакаллы картлары кычкырып тәкбир әйтә, карчыклар дога кыла, кечкенә балалары үксеп елый иде. Димәк, бу хатынның ире дә шулар арасында булган. Һәм исән калган. Һәм бу татарлар тагы бер-берләрен табышканнар, һәм әйбәт яшәп яталар. Ә аның хатыны күптән Иртәш зиратында ята инде, баш мие рагыннан күзгә карап кычкырып үлде ул. Бирeдә яшәп киткән Мәскәүдәге кызының балалары гарип, Иртәштә туган улы дауна чирле, туганнан бирле Сөнкүл

больницасында ята. Үзе әкренләп череп килә. Ә бу татарлар, әллә кайчан череп үләргә тиешле кыргый кавем, һаман җир тетрәтеп яшәп ята.

— Балаларың сау-сәламәтме соң? — дип сорап куйды карт, бугазына килеп төялгән ачуын йота алмыйча.

Гөлҗиһан аның бу соравыннан бераз югалыбрак калды, аның очраган бер кешегә гаилә тарихын, балалары язмышын сөйлисе килми иде. Әмма ул, беркатлы татар гадәте белән, сораган кешегә ялганлый да алмады. Нигәдер үзе дә дөм сукыр булган бу урыс картын кызганды ул һәм ничек бар, шулай әйтеп бирергә булды.

— Минем дә ирем сезнең кебек дөм сукыр, — диде ул. — Игезәк балаларыбыз тумыштан телсез һәм чукрак. Кече улыбыз хәзергә Аллага шөкер. Әмма монда сукыраю да, гарипләнү дә бик тиз шул.

— Нигә алай уйлыйсыз? — диде карт чекист, гадәтенчә төпченеп. — Миңа калса, безнең шәһәр яшәр өчен бик яхшы.

— Әйе, тыштан караганда, ул бик чиста күренә, — дип дәвам итте Гөлҗиһан. — Әмма без атом казаны өстендә утырабыз бит. Бөтен авырулар шуннан, радиациядән. Сукырлык та, телсезлек тә, бөтен шәһәрне басып киткән яман шеш тә.

Аның бу сүзләреннән карт чекист телсез калды.

Ничек инде бу хатын атом турында, радиация турында шулай ачыктан-ачык сөйләп утыра ала?! Бу бит алар ярты гасырга якын саклаган дәүләт сере! Элек моның турында сөйләү түгел, уйласаң да аталар иде! Менә нәрсәгә китерде бу «гласность» дигәннәре. Дәүләт сере урам хатыннары телендә. Шушының өченме ул ярты гасырга якын атом серен үзеннән дә артык күреп саклады? Атом комбинатында нинди зур шартлаулар булып та, аның хакында дөньяга бер хәбәр чыгартмады, берни белгертмәде. Моның өчен йөзләгән, меңләгән кешеләрне корбан итәргә туры килде, әлбәттә, әмма атом-төш коралы турында серне болай гына саклап була идеме соң? Ә хәзер әнә бөтенесе дә урамда икән...

— Ә сез каян беләсез аның шулай икәнен? — диде карт чекист, тирәнрәк төпченеп. — Бу хакта газеталарга язалармы, кешеләр сөйлиме?

— Иртәш турында, «Маяк» атом комбинаты турында газеталарга сирәк язалар, — диде Гөлҗиһан. — Чернобыль турында күп язалар бит хәзер. Ә бездәге бөтен авырулар нәкъ Чернобыльдәге кебек. Әзрәк башы булган кеше шунда ук аңлый инде моны.

Гөлҗиһан чыгып киткәч тә, карт озак тынычлана алмады.

Ул сизә: бу дөньяда бөтенесенең асты өскә килеп бара иде. Җиде кат җир асларына яшереп сакланган дәүләт сере инде өскә, урамнарга чыккан. Һәм бу сер белән бергә бик

күп нәрсәләр өскә чыгарга мөмкин иде. Илле җиденче елгы атом шартлавы да, шәһәрнең тоташы белән көчле радиация алуы да, шул вакытта ук «Маяк»ның ябылырга тиешлеге дә, атом пычрагы астында череп үләргә калдырылган татар авыллары да. Андагы кешеләр өстендә үткәрелгән тәҗрибәләр дә, Сөнкүл лабораториясе дә, дауна-тилеләр, гарип-горабалар да. Һәм шушыларның барысын кырык елдан артык дәүләт сере итеп саклаган КГБ генералы Ткаченколар да — барысы да берзаман өскә калкып чыгарга мөмкин иде. Ә ул моны теләми. Чөнки ул боларның барысын да ил өчен башкарды, дәүләт, партия өчен үзен дә, башкаларны да корбан итте. Ә ул ил юк инде. Юк... Сталин, Берия кебек дәүләт дәрәҗәсендә уйлый һәм эшли белерлек шәхесләр дә юк. Менә нәрсәгә эче яна сукыр генералның, менә нәрсәгә бер татар хатынының гап-гади сүзләреннән аның бөтен җаны актарылып чыкты. Ул аларны теге вакытларда ук бөтенләй юкка чыгармавына чын күңеленнән үкенде.

Ул чагында Караболак авылы икенче урынга күчерелергә тиеш иде, әмма Ткаченко командасы татарларны үлем зонасында калдыру өчен барысын да эшләде. Мәскәү алдында ул бу авылларның бередә, Иртәш янында кирәк булачагын исбатлый алды. Татарлар белән Ткаченконың үз исәп-хисабы бар иде. Кырымда аларның өннәрен үз куллары белән туздырганнан соң, сөрелергә чират Идел-Урал татарларына да җитәргә тиеш иде, моның өчен инде барысы да әзер иде. Әмма Ткаченконың планын Мәскәүдә кабул итәргә ашыкмадылар, һаман суздылар, бу эшне башларга һаман ниндер көттеләр. Ул арада, ниндидер хәвеф сизенеп, татарлар үзләре моңа каршы астан гына хәрәкәт итә башладылар, андыйга алар оста халык. Ул арада сугыш та бетеп куйды, Россия өчен мәңгелек баш бәласе булган Идел-Урал татарлары да үз урыннарында утырып калдылар. Ә шундый уңайлы мөмкинлек иде бит алардан мәңгегә котылырга, Себергә генә түгел, яңадан монгол чүлләренә сөрергә! Һәм шундый җай кулдан ычкынды.

Әмма Россиянең гомерлек тарихи дошманын бу җирләрдән башкача да юк итәргә була иде. Ткаченко командасы моның бөтен мәкерле алымнарын, бөтен серләрен белә иде. Шуңа күрә алар атом, радиация, химик һәм бактериологик корал белән бәйле бөтен объектларны, үлем полигоннарын татарлар яшәгән җирләрдә төзергә тырыштылар. «Маяк» атом комбинаты да нәкъ менә шуңа күрә татарларның төп Ватаннары булган Урал тауларында, Чиләбе өлкәсендә төзелде. Ткаченконың уйлавынча, атом һәм радиация бу тәкәббер татарларны җир белән тигезләргә, җир өстеннән юк итәргә тиеш иде. Ә алар әнә һаман яшәп, үрчеп яталар икән бит!

Дөрес, бу татар хатынының да балалары гарип икән, ире сукыр, ди. Авылда да күп үләләр, ди. Әмма барыбер яшиләр, җан саклыйлар бит! Югыйсә аларның атом болыты астында яши башлауларына ярты гасыр була бит инде!

Әмма картны эчтән иң ярсытканы — үзенең шушы кыргый татарлар кулына калуы иде. Кирәк бит аны карарга шушы Караболак хатынын билгеләргә! Ул бу хәлдә язмышның зур гаделсезлеген күрде, чөнки ул алар кулына калырга тиеш түгел иде. Киресенчә, алар аның кулына, күзенә карап, дер калтырап торырга тиеш иделәр. Гомеренең ахырында үзенең корбаннары белән бу хәлендә очрашырга теләми иде ул. Югыйсә ул татарлар инде күптән кырылып, көеп бетәргә тиеш иделәр. Ә юк, кайсы — юрист, кайсы — табиб, бөтенесе укыган, белем алган, Иртәшнең үзенә килеп, дөньяга хуҗа булып яшәп яталар икән! Аларны хәтта атом бомбасы да ала алмаган. Һәм иң куркынычы — нәселләре дәвам итә. Менә аныкы бетте, улы тиле, хәтта үз атасын да танымый, кызының балалары тере гарип. Боларның әле сәламәт уллары бар икән. Алардан шул бала калыр, ә КГБ генералы Ткаченкодан нәрсә калыр? Югыйсә ул бөтен җаны-тәне белән СССРга, Россиягә хезмәт итте бит. Урыс милләтен бу җирләрдә мәңгеләштерү өчен барысын да эшләде. Кырымнан, Кавказдан бөтен милләтләрне чүлгә сөрде, исән калганнарын радиация белән көйдерде. Һәм нәтиҗәдә ул, КГБ генералы Ткаченко, дөм сукыр хәлдә, аягүрә череп, нәселе бетеп, шушы татар хатынының кулына карап ята. Ни өчен?!

## Алтынчы бүлек

Ткаченко үзе турында бик ачылып бетмәсә дә, Гөлҗиһан аның кемлеген сорашып белде: бу сукыр карт КГБ генералы булып чыкты. Шәһәрдә аны белүчеләр шактый икән, малаеның шыр тиле икәнлеген, Сөнкүлдә ятуын да әйттеләр, кызының балалары да церебраль параличлы булып туганнар икән. Мәскәүдә яшәүче кызы аны үз янына чакырмый да, кертми дә икән. Ул, генерал дәрәҗәсендә булса да, хәзер туган-тумачаларына кирәк түгел булып чыккан. Дөрес, Иртәш шәһәре җитәкчелеге аны ташламый, карап, ярдәм итеп тора икән, әмма алар берсе дә якыннарны, балаларны алыштыра алмый шул. Гөлҗиһан бу сукыр картны чын күңеленнән жәлләде, җылы сүзе белән булса да аңа ярдәм итәсе, күңелен күрәсе килде.

Картның Караболак турында нидер белүе дә аны бик кызыксындырды, әмма бу хакта тагы үзеннән сорарга уңайсызланды. Авылга кайткач, ул аның турында Таһирҗан бабасы-

на әйтте. Ни гаҗәп, Таһирҗан бабасы моннан кырык еллар элек булган хәлләрне бик яхшы хәтерли булып чыкты. Бу кешене дә белә икән.

— Син аннан ерак тор, кызым, начар бәндә ул, — диде Таһирҗан карт, теге вакытта Караболакка килгән урыс генералын күз алдына китереп. — Безнең авылга эт кебек ябырылды ул. Котырган эт кебек каныкты. Каенатаң мәрхүм Якупның гаиләсен ул Караболактан карап торып кудырды. Аларны яклаган өчен, атаңны утыртып куя язды, чак алып калдык. Теге вакытта, Иртәштә шартлау булгач, Караболакны да башка урынга күчерәсе булганнар, бу бәндә каршы төшкән. «Караболак күчерелде» дип, Мәскәүгә рапорт биргәннәр дә шушында үлеп бетәргә калдырганнар. Хәтерләсәң, шул елларда ук бөтен документлары белән авыл советы һәм мәктәп ябып китте, анысы да шушы бәндәләр эше иде, исбатлый гына алмадык. Элек бит болар хакында авыз ачарга да ярамый иде. Еллар буе кайда яшәвебезне дә исбатлый алмадык, документларыбыз булмады. Бутады ул вакытта ул урыс генераллары халык башын, бутады. Нинди үче булгандыр шундый зур кешенең бу авыл татарларында? Бер Алла белә. Ә син аннан ерак тор, кызым, синең җәлләүгә лаек түгел ул, көчеңне әрәм итмә...

Таһирҗан картның бу сөйләгәннәреннән Гөлҗиһан телсез-өнсез калды. Менә кем белән очраштырган икән аны язмыш! Ирен сөргенгә сөрүче белән. Әтисен төрмәгә тыгарга тырышучы белән. Караболакны радиация астында үлемгә дучар итүче белән. Ә карап торышка бер мескен карт кебек. Дөрес, ул да язмыштан аласын алган инде, кылган явызлыклары өчен җәзаны бу дөньяда вакытта ук күргән. Тик моны белүдән Гөлҗиһанга ни файда, аның сукыр иренә, гарип балаларына, үлем көтеп яткан Караболак халкына ни бирә боларны белү? Алар күргән газаплар өчен әле җавап бирүче, тәүбә итүче, чара күрүче юк бит! Барысы да нәкъ элеккечә дәвам итә. Димәк, бу шымчы карт та үзе исән вакытта барысы өчен дә тәүбә итәргә, дөреслекне ачарга ярдәмгә килергә тиеш. Бу авыруларның Иртәштәге радиация белән бәйле булуын аннан да яхшы тагы кем белә? Тик ничек башларга аның белән бу хакта сүзне? Ул, ни дисәң дә, больницада ятучы авыру кеше бит, һәм Гөлҗиһанның аны ирексезләргә бернинди дә хакы юк. Сорау алырга — бигрәк тә.

Ни гаҗәп, бу юлы Ткаченко үзе аны түземсезлек белән көтеп каршы алды. Чөнки аның кем белән булса да дөнья турында иркенләп сөйләшеп утырасы килә иде. Һәм беләсе, күбрәк беләсе: халык ни уйлый бу үзгәрешләр турында, озакка барырмы бу буталчыклык? Иртәшкә, дәүләт серенә зыян килерлек түгелме бу перестройка дигәннәре. Бу татар хаты-

ны эчкерсез кешегә охшаган, андыйларның эчендәге тышында була. Ә Ткаченкога шул гына кирәк тә, чөнки ул, пенсиядә булса да, бөтен барлыгы белән барыбер шушы илгә хезмәт итә, шымчы булып кала.

Күңелендә бу кешегә карата ачу кайнаса да, Гөлҗиһан эчендәген тышка чыгармады, чөнки биредә бу карт — авыру, ә Гөлҗиһан табиб иде. Димәк, сүз-гамәлләрдә шул чикне узарга ярамый, шәхси мөнәсәбәтләрдә артык тирән керү килешми.

Ткаченко аннан һаман шәһәр һәм авыл тормышы турында сорашты. Аның өчен халык фикере бик мөһим иде.

— Халык ялганнан туйган иде инде, — дип кыска тотарга тырышты Гөлҗиһан. — Ичмасам, дөресен белдек.

Ткаченко сагаеп калды. Нинди дөреслек? Иртәштәге атом комбинаты турындамы, үлем зонасында утырып калган Караболак турындамы, әллә инде Ткаченко командасының бу эшләрдә тоткан урыны турындамы? Аның ярты гасыр бу ил өчен баш күтәрми эшләве, дәүләт серен үз тормышыннан да артык күреп саклавы шулай бер мизгелдә кирәксезгә, юкка чыктымы икәнни?

— Нинди дөреслек турында сөйлисең, сеңелем? — диде ул, Гөлҗиһанны өркетмәскә тырышып. — Без барыбыз да дөрес яшәмәгән булып чыгамыни инде?

Ткаченконың, «без» дип, үзен дә халык язмышы белән бәйләп куярга тырышуы Гөлҗиһанга ошап бетмәде, әмма ул аңа каты бәрелмәде. Бу сукыр картка хәзер нәрсә әйтсәң дә соң инде. Дөньяның барышы, бу үзгәрешләр хәзер аның фикереннән тормый. Әле ярый аның фикереннән тормый.

— Соң, абзый, без бугаздан атом калдыклары арасында утырабыз икән бит, — диде ул туп-туры. — Безнең бөтен авыруларыбыз шул радиациядән икән. Шул исәптән сезнең сукыраюыгыз да, гарип балаларыгыз, оныкларыгыз да. Сез саклаган дәүләт сере, атом бомбасы менә нәрсәгә төште безгә. Үзебезнең өстә шартлады.

Гөлҗиһан бу сүзләрне шулхәтле гадәти итеп әйтте, Ткаченко бертын өнен җыя алмый торды. Нәрсә сөйли бу хатын?! Ничек беркемнән курыкмыйча, шушылар турында сөйли ала ул? Һәм кемгә сөйли диген?! Гомер буе шушы серне саклаган КГБ генералына, карт чекистка! Әгәр илдә, Иртәштә бөтен кеше шулай уйласа, бу — бетү дигән сүз. Инде СССРның гына түгел, Россиянең дә таркалуы дигән сүз. Чөнки карт генерал белә: бу ил корал көче белән генә тора, ә атом коралы — аларның иң көчле куркыту, буйсындыру чарасы.

Әмма карт чекист үзен кулга алырга, эчке ярсуын сиздермәскә тырышты. Бу авыл хатыны белән бәхәсләшеп утырудан ни файда? Аңа бары тик халык фикерен, кешеләрнең ни уйлауларын гына белергә кирәк.

— Бөтен кеше синең кебек уйлыймы, сеңелем? — диде ул, салкын канлылык сакларга тырышып.

— Бөтенесе ничек уйлыйдыр — белмим, әмма мин үзем шушы фикергә килдем инде. Чөнки мин гомер буе шушы сорауга җавап эзләгән идем.

— Нинди сорауга?

— Нигә безнең Караболак халкы бу хәтле күп чирли һәм үлә, дип уйладым мин гомер буе. Чөнки үзем дә нәкъ алар кебек авырый идем. Ул вакытта Чиләбе больницасында да тикшертеп караган идем авыл халкының авыру тарихын, дөресен әйтмәделәр, анализларын бирмәделәр. Менә хәзер белдем: Караболакта соңгы утыз елда үлгән кешеләрнең барысында да рак булган икән. Меңнән артык кешедә нурланыш чире! Моның шулай икәнлеген медиклар шул вакытта ук белгән бит инде, ә халыктан яшергәннәр. Аларның барысының да авыру тарихларына «гомуми авыру» дип язылган. Алар бит бер төймә даруга тилмереп, хөкүмәттән берниндиярдәм күрмичә үлделәр. Югыйсә Иртәштә атом шартлавыннан шушы хәлгә килде бит авыл халкы. Безнең авыл янындагы урыс авылларын башка җиргә күчерделәр, ә без атом пычрагы астында утырып калдык. Ә Мәскәүгә «Караболак күчерелде» дип рапорт биргәннәр. Сез менә ул вакытта зур кеше булгансыз, әйтегез алайса, нигә халыкны күрә-күрә үләргә анда калдырдылар?

Ткаченко хәзер генә аңлап алды — бу бер дә беркатлы, аңгыра авыл хатыны түгел, бу инде мәсьәләнең төбенә төшеп җиткән куркыныч кеше иде. Ул кирәгеннән артыкны белә. Тыелган, ярамаган нәрсәләр турында сөйли. Димәк, аның белән телне сак тотарга кирәк. Теге еллар булса, әле Ткаченконың күргән вакытлары гына булса да, ул бу хатынга тиз авызлык кидерер иде. Чөнки һәр заман өчен дә тыелган әйберләр бар, һәр илнең дә үз дәүләт сере бар. Ә бу хатын, авыз тутырып, чат саен шуларны сөйләп йөри. Әгәр ул үз авылларын ни өчен күчермәү сәбәбенә дә барып җитсә? Бу бит инде бер Ткаченконың гына сере түгел, монда күп кешеләр катнашкан. Хәер, аларына ук барып җитә алмас, чөнки бу эшләр берсе дә кәгазь язып эшләнмәде, эз калдырылмады. Әгәр бу эшләрдә Ткаченконың кулы уйнаганын белсә, ул болай ачылып сөйләшеп утырмас иде, суд юлында өстерәп йөртә башлар иде. Хәзер бит шундый заман, шундыйлар заманы. Димәк, аны мөмкин кадәр тынычландырырга, буташтырырга кирәк. Кешене куркытып тыеп булмый икән, башка төрле юл белән, ышанычка кереп коралсызландырырга кирәк...

— Әйе, хәтерлим, Караболак авылы күчерелгәннәр исемлегендә бар иде шул, — диде карт чекист, инде үзен тәмам

кулга алып. — Дөрестән дә, Мәскәүгә бу хакта рапорт киткән булырга тиеш. Әмма, соңыннан ачыкланганча, бу көчәрелгән авыл Урыс Караболагы булып чыкты. Караболак, Караболак. Шулай язганнар да җибәргәннәр инде. Ул заманда бит наданлык та көчле, урысын-татарын тикшереп тормаганнар.

— Ә нигә, алайса, соңыннан, бу хәлләр ачыклангач күчермәгәннәр? — диде Гөлҗиһан, картның хәтеренә хәйран калып.

— Соңыннан... Ә соңыннан, хәтерем ялгышмаса, авылыгызны тикшереп карадылар да аның радиациядән зарар күрмәвен ачыкладылар. Ягъни илле җиденче елгы шартлау вакытында атом болыты сезнең авыл өстеннән узмаган булып чыкты, монысын галимнәр ачыклады. Шуңа күрә иген кырларын да яңадан халыкка файдалануга кайтарып бирделәр. Халык нормально яши башлады.

Гөлҗиһан бу карт шымчының елгырлыгына хәйран калды.

Кара син аны, барысын да ничек оста китереп чыгарды бит! Черки борынын тыгарлык түгел! Имеш, башта ялгышканнар, аннан инде Караболакның радиациядән зарар күрмәгәнен ачыклаганнар икән болар. Ә йорт саен көн дә булып торган үлемнәрне кая куясың, авыл тулы чирлене, гарип-горабаны кая куясың?! Яман шеш авыруы белән дөньядан киткән меңнән артык кешене кая куясың?!

— Ә халыкның бу хәтле үлеме нәрсәдән килеп чыккан соң алайса? — диде Гөлҗиһан, эчке ярсуын көчкә тыеп. — Авылны басып киткән рак чирен кая куясың?

— Ә хәзер кайда авырмыйлар — заманы шундый бит, — дип, шома гына җавап бирде карт чекист. — Кеше туа тора, үлә тора, ә тормыш барыбер дәвам итә. Караболак та бетмәгән бит, үзегез шулай әйттегез беренче көнне. Үзегезнең дә өч балагыз үсеп ята икән. Менә шуңа сөенеп яшәргә кирәк дөньяда, әллә кайчан булган хәлләр белән баш катырып түгел, сеңелем.

Гөлҗиһанның бу карт төлке белән башка бәхәскә керәсе килмәде. Аның өчен барысы да ачык иде инде...

Дәүләт, атом аталары, КГБ шымчылары беркайчан да Караболак фаҗигасен үз өсләренә алмаячаклар. Алар өчен бер татар авылының язмышы, аерым кешеләрнең газаплары нәрсә?! Бернәрсә дә түгел. Алар өчен атом бомбасы адәм баласына караганда мөһимрәк, кадерлерәк. Хәтта бу корал үз халкына каршы эшләсә дә, аларны меңәрләп кырып салса да. Карт чекист белән сөйләшүдән соң, Гөлҗиһан боларны тагы да яхшы аңлады.

Гөлҗиһан белән сөйләшкәннән соң, Ткаченконың да эченә шом кереп калды. Ул җан тынычлыгын югалтты. Дөрес, ул бу үҗәт татар хатынын үз урынына утыртты, башын бу-

тап чыгарып җибәрде. Әмма ул аның бу нәрсәләр хакында ни дәрәҗәдә белүен белми иде. Караболак фаҗигасендә Ткаченконың нинди роль уйнавын беләме икән ул? Аның ирен, әле бала вакытта, карап торып Ткаченко үзе сөрдерүен беләме икән? Белсә, ниләр эшләргә җыена икән? Күзле чагы булса, ул үзе чарасына керешер иде, бу хатынга мең төрле проблема тудырыр иде. Ә хәзер ул үзе кеше кулына карап ята шул. Тик бу хатын белән барыбер араны өзәргә кирәк, больницада шәфкать туташы бетмәгәндер, башканы куйсыннар аның янына. Юкса берәр зыян салуы бар.

Ткаченко, больницаның баш табибын чакыртып алып, үзенә башка шәфкать туташы билгеләүләрен сорады. Аннан үзенең элеккеге хезмәттәшләрен чакыртып, Гөлҗиһанның үзе һәм гаиләсе белән ныклап кызыксынырга кушты, аларны күзәтү астына алырга боерды. Ул больница палатасында да КГБ генералы булып калуын дәвам итте, боларны Иртәшнең куркынычсызлыгы белән бәйләп аңлатты. Бу хатын аның эзенә төшкәнче, биредә ярты гасыр барган яшерен эшләрне дөньяга фаш иткәнче, аны үз урынына утыртырга кирәк иде. Урыс генералы, дөм сукыр хәлендә булса да, дөреслеккә каршы соңгы сугышын башлады. Меңәрләгән кешене юк иткән дәүләт сере аның өчен барысына караганда да мөһимрәк иде. Чөнки бу дәүләт сере белән бергә, аның эшләре дә ачылачак иде. Палачлыгы дөньяга беленәчәк иде.

Ткаченкодан ишеткәннәре, Чиләбе больницасыннан алынган авыру тарихлары Гөлҗиһанның бик күп нәрсәләргә күзен ачты. Ул элек тә бу илгә, бу җитәкчеләргә ышанып бетми иде, хәзер исә аларга нәфрәт белән карый башлады. Ничек инде халык хәтле халыкны шулай үлемгә дучар итәргә мөмкин? Кемнең нинди хакы бар моңа? Һәм болар өчен кем җавап бирергә тиеш?

Ул елны гает бәйрәме көзге көннәрнең берсенә туры килде. Гөлҗиһаннар да, балаларын төяп, тагы Караболакка кайтып төштеләр. Иртәштә мәчет юк, шуңа күрә анда яшәүче Караболак халкы гает бәйрәмнәренә авылга кайтырга тырыша иде. Быел да авылга читтән кайтучылар күп булып чыкты, Караболак элеккеге бәхетле чакларын хәтерләтеп куйды.

Караболак мәчете — тирә-якта иң борынгы мәчетләрнең берсе, аның салынуына инде өч йөз ел тирәсе бар икән. Заманалар үзгәргәч, мәчеткә йөрү дә тыелмый башлады, шуңа күрә гаетләрдә халык мәчеткә сыймый. Бу юлы да шулай булды, халыкның бер өлеше гает намазын мәчет алдындагы мәйданга җаймәләр җәеп, шунда укыды. Фәргать белән Гөлҗиһан да, балаларын ияртеп, авылдашлары янына килеп бастылар. Эчтән микрофон аша Таһирҗан бабайның сузып-сузып азан әйткәне, Коръән укыганы ишетелә иде.

Гает намазыннан соң халык, гадәт буенча зиратка китте.

Бу көнне кем әрвахлар рухына дога кыла, кем зират өстен чистарта, каберләрне тәртипкә китерә. Халыкны бу юлы да кара урман кебек шаулап утырган, авыл башыннан чакрымнарга сузылган чардуганнар шәһәрлеге каршы алды. Аяк астына шаулап сары яфраклар коела, нәкъ теге еллардагы кебек матур, алтын көз иде. Тик ул көннәрдәге халыкның гына күпчелеге менә шушы зиратларга күчеп беткән.

Халык зират янына җыелып сөйләшеп торды. Барысының да телендә дөньядан вакытсыз киткәннәр, каты газаплардан соң шушы зиратларга күчкәннәр иде. Халык әле һаман бу авыруларның да, үлемнәрнең дә сәбәбен белми иде.

— Гаеп итмәсәгез, бер сүз әйтим әле, авылдашлар, — дип башлап китте Гөлҗиһан, зират буенда басып торган халыкка карап. — Бу үлемнәр барысы да Иртәштәге атом шартлавы аркасында, радиация сәбәпле бит. Мондагы шартлау Чернобыльгә караганда күпкә артык булган, ә халыкка берни әйтмәделәр... Менә шуңа күрә чирлибез без, шуңа үләбез. Беркем бернәрсә белми, беркем бернәрсәгә җавап бирми. Үзебез берәр нәрсә эшләмәсәк, тиздән бөтенебез менә монда күчеп бетәчәк.

Халык шомланып тынып калды. Күпләр теге вакытта Иртәштә нидер шартлаганын белә иде. Ул вакытта Караболакны башка урынга күчерергә дә йөрделәр, коеларны җимерделәр, елгага юлны яптылар. Аннан барысы да искечә калды. Кеше артыннан кеше үлде, Чиләбедән килеп тикшерә тордылар, халык кырыла торды.

— Нишләп карыйк соң, кызым? — диде Таһирҗан карт, барысы өчен дә сорап. — Теге елларда йөреп караган идек, берничә ирешә алмадык. Безнең авыл картада да юк бит ул, документларда да юк, менә эш нәрсәдә.

— Патшага хат язарга кирәк! — дип кычкырып җибәрде чардуганнар арасына кереп качкан Рәшидә. — Мәскәүгә, ак патшага хат язарга кирәк, нигә Караболакны әбижәт итә алар?

Барысы да моңсу гына елмаешып куйдылар.

— Әйе, Ельцинга хат язып карарга кирәк, — диде Гөлҗиһан, классташының сүзләрен җитдигә алып. — Безнең башка чарабыз юк. Мин Чиләбе больницасы аша тикшерттем — бу зиратларда ятучыларның барысында да рак булган, ә аларны беркем дәваламады, бернинди ярдәм күрсәтмәделәр. Без дә шушы илдә яшибез, аның өчен эшлибез югыйсә. Ни өчен башкаларны күчергәндә дә, Караболакны, белә торып, радиацияле урында череп үләргә калдырганнар? Моңа кем гаепле? Безгә алга таба нишләргә? Менә шушы сорауларны куярга кирәк Россия Президенты алдына.

Һәм шушыларның барысын да әйтеп, Гөлҗиһан Россия

Президентына хат язып җибәрде. Караболакның меңәр еллык тарихы турында да, анда яшәүче тырыш татар халкы турында да, аларның тормышлары, дин-мәгърифәтләре турында да язды ул. Аннан 1957 елгы хәлләрне тасвирлауга күчте, Иртәштәге атом шартлавыннан соң авыл халкының күпчелеге рактан үлеп бетүен әйтте. Үзенең дә әле бала вакытында атом калдыкларын чистартуда катнашуын, шуннан соң гел авыртуын, хәзер рак белән чирләвен язды. Шушы хәлләргә карамастан, Караболак халкының дәүләттән берниндиярдәм күрмәүләрен, ташламалары булмавын, авыр хәлдә, бүген дә радиация арасында яшәүләрен тасвирлады. Ул Россия Президентыннан бу мәсьәләләрне хәл итүдә ярдәм сорады, Караболак авылын да статусларында чернобыльчеләр белән тигезләүләрен үтенде.

Гөлҗиһан бу хатка авылдашларыннан да имза җыйды. Караболакның исән калган бөтен татарлары аңа кул куйды.

Караболак тарихында өр-яңа чор — Россия дәүләте белән көрәш чоры башланды.

Бу көрәшнең башында татар хатыны Гөлҗиһан тора иде...

## Җиденче бүлек

Әйе, Чернобыль фаҗигасенә юл Көньяк Уралдан, Иртәштән башлана.

Ярты дөньяны агулап өлгергән Чернобыльне тиз генә ябып куялар, ә Иртәш аннан соң да тирә-якка радиация таратуын дәвам итә. Анда берсе артыннан икенчесе төрле аварияләр, шартлаулар булып тора, әмма ул хакта хәбәрне дөньяга чыгармаска тырышалар. Илдә башланган хуҗасызлык һәм башбаштаклык ябык атом зоналарына да килеп җитә. 1990 елның 16 ноябрендә атом реакторында көчле шартлау була, тирә-юньгә радиация тарала, кешеләр үлә... «Маяк» атом берләшмәсендә шундый ук ватылу-җимерелүләр 1993 елның 17 июлендә, шул ук елның 2 августында, аннан 27 декабрендә була, Иртәш өстенә һәм тирә-якка радионуклидлар тарала. 1994 — 1995 елларда исә «Маяк»та тугыз атом авариясе була. Әмма атом аждаһасы барыбер эшләвен дәвам итә. Аның бер башын кисеп ташласалар, урынына икенчесе үсеп чыга.

Әмма Чернобыль фаҗигасе Иртәш буенда яшәүчеләрнең дә күзләрен ача. Бөтен Чиләбе өлкәсе буйлап экологлар һәм хокук яклаучыларның атом-төш коралына каршы көчле хәрәкәте башлана. Алар халыкка «Маяк» атом берләшмәсе турында дөрес мәгълүмат чыгаралар, бу авыруларның ради-

ация, «Маяк»тагы шартлаулар белән бәйле икәнлеген аңлата башлыйлар. Бу хәрәкәт хәтта татар авылларына да үтеп керә, халык үзен чернобыльчеләр белән бер дәрәҗәгә куюны таләп итә, бу мәсьәлә буенча судлар башлана. Һәм тарихта беренче тапкыр 1990 елны «Маяк» фаҗигасе Мәскәүдә, СССР Югары Советында карала. 1991 елның җәендә, Россия Президентын сайлаулар алдыннан, бу якларга, татар авылларына Борис Ельцин килеп китә. Халык аннан үзләренә карата махсус закон кабул итүне, «Маяк»тан зарар күрүчеләрне чернобыльчеләр белән тигезләүне һәм радиацияле җирләрдә яшәп яткан татар авылларын башка урынга күчерүне таләп итә. Ельцин ризалык бирә.

Чиләбе өлкәсенә Мәскәүдән зур-зур комиссияләр, тикшерүләр килеп җитә.

Өлкәдә ярты миллионга якын кешенең «Маяк»тан зарар күрүе, радиация алуы, нурланышка дучар булуы ачыклана. Иртәштә җир астында һәм җир өстендә бер миллиард кюри атом калдыклары саклануы билгеле була. Бу исә бөтен дөньяны, Җир шарын бер мизгелдә юк итәргә җитә. Бу коточкыч хәбәр дөнья җәмәгатьчелеген аякка бастыра, Чиләбе өлкәсендәге татар авылларына — Мөслимгә, Татар Караболагына, Мусакайга чит илләрдән галимнәр, табиблар, экологлар, хокук яклаучылар, журналистлар агыла башлый. Атом фаҗигасенә дучар булган татар авыллары турында хәбәр бөтен дөньяга тарала.

Ниһаять, 1993 елны Россия Югары Советында «Маяк» атом берләшмәсеннән зарар күргән халык өчен махсус закон кабул ителә. Әмма Татар Караболагы авылы 1957 елгы атом фаҗигасеннән зыян күрүчеләр исемлегенә кертелми. Чөнки андый авыл рәсми кәгазьләрдә булмый, исәптә тормый. Ул 1958 елда башка урынга күчерелгән булып санала.

Бу вакытта инде дүрт меңлек авылдан нибары җиде йөз кеше калган була.

Татар хатыны Гөлҗиһан, менә шуларның барысын да әйтеп, Россия Президенты Борис Ельцинга хат язып җибәрә. Мәскәү аның хатларын Чиләбегә юллый, Чиләбе исә, «Татар Караболагы авылы радиациядән зарар күрмәгән» дип, рәсми җавап бирә. Чөнки авылның, чыннан да, радиациядән, «Маяк»тагы шартлаудан зарар күрүен исбатларлык бер генә документы да булмый. Авылның үзенең дөньяда барлыгын исбатларга да дәлиле булмый. Менә шундый шартларда татар хатыны Гөлҗиһан империя аждаһасы белән тиңсез көрәшкә чыга.

Аның артында, ярдәм көтеп, инде үлеп барган Караболак халкы тора.

Аның артында, ярдәм көтеп, өч баласы тора.

Алып Ханнар нәселе, татар милләте тора...

## Сигезенче бүлек

Соңгы вакытта Гөлҗиһаннар Иртәштәге дала кебек фатирларында өчәү генә яшәп калдылар. Игезәкләр Иртәштәге телсез-чукрак балалар өчен махсус мәктәп тәмамладылар да шушы юнәлештә Чиләбегә китеп бардылар. Чөнки андый балаларга һөнәр бирә торган махсус училище Чиләбедә генә иде. Башта балаларын үзеннән аерып чыгарып җибәрү авыр булса да, Гөлҗиһан аларның һөнәр алуларын, үз ишләре янында булуларын теләде. Бәлки, атом казаны өстендә утырган Иртәштә калдырасы да килмәгәндер. Дөрес, Чиләбедә дә ул яктан чиста түгел, радиация өчен чикләр юк, әмма алар атом бомбасы өстендә утырмыйлар. Шулай итеп, игезәкләр Чиләбегә барып урнаштылар, Фәргать белән Гөлҗиһанга юанычка Баһадур калды. Аларга олыгайган көннәрендә Алла биргән бала, ут чаткысы кебек, сау-сәламәт бала, әти-әни дип өзелеп торган бала. Акылы белән могҗизага тиң бала.

Чыннан да, Баһадур бөтен яктан да шаккатыргыч бала иде.

Аның теле бик иртә ачылды, ул, шаркылдап көлә-көлә, Фәргать белән Гөлҗиһан артыннан бөтен сүзләрне кабатлап барды. Баштарак алар бу хәлдән курыктылар, бишектәге Гайсә пәйгамбәр кебек, Баһадур да аякка басканчы телгә килде. Әйтерсең лә бала сүзенә тилмергән әтисен шулай сөендерергә теләде, әнисенә җан тынычлыгы бирде. Бу могҗизаны карарга бөтен тирә-күрше җыелды. Моңа кадәр Иртәштә әле бишегендә сөйләшә башлаган баланың туганы юк иде. Кемдер моны заман ахыры белән бәйләде, кемдер радиациянең кире мутациясеннән күрде. Баһадур имән чикләвеге кебек таза, нык бала иде, аның тавышы да күк күкрәвен хәтерләтә. Нәкъ татар әкиятләрендәге Алпамша инде, Таһирҗан бабай сөйләгән Алып батыр. Улының артык әзмәверлегенә Гөлҗиһан башта куркыбрак караса да, авылга кайткач, Таһирҗан бабасы тынычландырды аны. Аларның нәселендә мондый пәһлеваннар булгалаган икән, Гөлҗиһанның әтисен дә Алып Адәм Нәби дип йөрткәннәр. Фәргатьләр ягыннан да андый зур гәүдәле ир-атлар булган, димәк, бала ике яктан да көч-гайрәтне үзенә алган.

Әкиятләрдәге Алып батырлар кебек, малай ай үсәсен көн үсте, көн үсәсен тиз үсте, иртә сөйләшә башлады, иртә йөреп китте, иртә сугышып кайтты, иртә өлгерде. Ул гәүдәгә генә түгел, акыл ягыннан да үз ишләреннән бик күпкә алда, бик күп белә иде. Аның кызыксынмаган нәрсәсе калмады. Ул сукыр әтисе өчен аның күрер күзләре булды, телсез-чукрак туганнарына тел һәм колак иде, ә әнисе өчен җан юанычы. Шушы терекөмеш кебек тере балага карап, Гөлҗиһан үзенең

бу дөньяга ни өчен килүен, ни өчен яшәвен аңлады. Барысы да Баһадур өчен булган икән. Язмыш аны шушы бала хакына, ул туугa сәбәпче итеп, Фәргать белән очраштырган, кавыштырган, авыру һәм үле балалардан соң менә шушы тере могҗизаны биргән. Йосыф пәйгамбәр кебек нурлы йөзле, Алып батыр кебек гайрәтле, Локман хәким кебек зирәк акыллы бала иде Баһадур.

Баһадур тугач, Фәргать бөтенләй үзгәрде, ул яңадан бала чагына, Караболакта үткән малай чагына әйләнеп кайткан кебек булды. Ул аны куллары, бармаклары белән яратты, йөрәге белән күрде, җаны белән тойды. Улының гөрләп сөйләшүен Фәргать көннәр буе армый тыңлап утыра ала иде. Әмма улы бераз үсә төшүгә, ул аның кайбер сорауларына җавап таба алмый башлады, чөнки малайның кызыксынуы дөньяга сыярлык түгел иде. Баһадур Җир белән дә, җиһан белән дә кызыксына иде, ул атасына фән-техника, медицина буенча да сораулар биреп йөдәтте, вакытыннан алда үзлегеннән физика, химияне өйрәнә башлады. Баһадур белән бергә тын өйгә төрле техника, радиоаппаратуралар кереп тулды, аның бүлмәсе космодромны хәтерләтә башлады. Баһадур урамда ни күрсә, барысын да өйгә ташый, сынап карый, әллә нинди тәҗрибәләр уздыра. Бераз үсә төшкәч, ул әнисеннән туп-туры сорап куйды:

— Әни, нигә безнең әти күрми ул?

Гөлҗиһан югалып калды. Чөнки ул үз улын белә: аңа дөрес җавап кирәк, икеле-микеле, аңлаешсыз җавапны ул кабул итми.

— Солдатта хезмәт иткәндә, авариягә эләккән ул, улым, — диде Гөлҗиһан, үзе белгәнне әйтеп. — Шуннан шундый булып калган.

— Ул яңадан күрә башлаячакмы соң?

— Белмим, улым. Баш белән бәйле шул ул. Алдагысы Алла кулында инде.

Баһадур шактый вакыт дәшмичә, үзенекен уйлап йөрде. Аннан тагы тып итеп әнисе янына килеп басты. Кое төбеннән килгән кебек көчле күкрәк тавышы белән тагы сорап куйды:

— Әни, апа белән абый нигә сөйләшмиләр алар?

Гөлҗиһанга монда да дөресен әйтми хәл юк иде.

— Алар тумыштан шундый булып тудылар, улым, — диде ул. — Ишетмиләр дә, сөйләшмиләр дә.

— Алар яңадан ишетә-сөйләшә башлаячакларммы соң?

— Белмим, улым. Баш белән бәйле ул. Алдагысы Алла кулында инде.

Кечкенә Баһадур берничә көн бик нык уйланып, сөйләшмичә йөрде. Аннан бүлмәсенә кереп бикләнде. Бүлмәдән шал-

тыраган, чыжылдаган тавышлар ишетелеп торды, өй эченә әче төтен исе таралды.

— Улым, нишлисең анда? — дип борчылып сорады Гөлҗиһан, ишек төбенә килеп басып.

Ишектә Баһадур үзе дә күренде. Аның йөзе корымга баткан, бүлмәсендә исә нидер пыскый, бөтен җиргә төтен исе таралган иде.

— Мин баш миен төзәтә торган машина ясыйм, әни, — диде ул, бик җитди рәвештә. — Ул машина эшли башлагач, әтинең күзе ачылачак, апа белән абый сөйләшә башлаячаклар. Мин аның сызымын да үзем сыздым, үзем җыйдым, хәзер тәҗрибә уздырасы гына калды.

Улының бу сүзләреннән Гөлҗиһан еларга да, көләргә дә белмәде. Бүлмәдә әллә ниткән приборлар таралып ята, каян җыеп бетергән ул аларны? Каян өйрәнгән ул мондый төгәл сызымнар сызарга, техника белән эшләргә? Моңа бит олы кешенең дә башы җитми. Менә нәрсәләр уйлап йөри икән бу бала. Каян килгән аңа мондый фикер? Димәк, ул атасының да, туганнарының да гариплеге белән килешми, бала акылы белән үзенчә чыгу юллары эзли. Әмма бу хәтле тирән кереп, үзенең башына зыян килмәсен, ут-күз чыкмасын.

— Ясарсың, улым, ясарсың, — диде ул, аны хуплап. — Әмма аның өчен күп укырга кирәк, ә син мәктәпкә быел гына барасың әле.

Мәктәп сүзен аптыраганнан гына әйтте Гөлҗиһан, чөнки Баһадур ике яшь ярымнан инде укый-яза белә. Ул өйдәге бөтен китапларны укып бетерде инде, игезәк туганнарының мәктәптән биргән өй эшләренә хәтле эшләп бирә иде ул. Бу гадәти бала түгел иде, әлбәттә, Баһадур — ахырзаман баласы иде. Гөлҗиһан эшләгән больницага Мәскәүдән килгән табиблар, галимнәр аның белән бик кызыксындылар, Баһадурны үзләре белән алып китәргә теләделәр. Әмма Гөлҗиһан ризалашмады, баласының башын тәҗрибә өстәленә саласы килмәде аның. Баһадурның кан анализларында бераз үзгәреш сизсә дә, ул аны Иртәштә генә дәвалап карарга булды, аңа үзе белгән даруларны, үлән-суларны бирә башлады.

— Мин ашыкмас идем, әни, вакыт ашыга, — диде ул, Гөлҗиһанны тагы гаҗәпләндереп. — Әтине тизрәк күзле итәсем килә, аның мине күргәне юк бит әле. Апа белән абый да сөйләшә башларга тиешләр, мин аларның тавышын ишетергә телим…

Ни гаҗәп, Гөлҗиһан улына ышанды… Чөнки ул да гомере буе ниндидер могҗиза көтеп яшәде. Көннәрдән бер көнне иренең күзе ачылыр кебек тоела иде аңа. Игезәк балалары да берзаман сөйләшә башларлар, «әти-әни» дип эндәшерләр

сыман иде. Улы Баһадурга ул тере могҗизага караган кебек карады, күңеле белән аннан нидер көтте, аларның гаиләсенә килгән бу бәла-казалардан кече улы коткарыр кебек тоела иде аңа. «Ә нигә, хәзер әллә нәрсәләр уйлап табалар бит, — дип хыялга бирелә иде ул кайвакытта балалар кебек. — Хәтта ясалма кеше, ясалма ми турында сөйлиләр. Адәм баласы хәзер әллә нәрсәләргә сәләтле. Бу хәтле күп кораллануга киткән көчне, акылны кеше өчен бирсәң, фәнгә, медицинага тотсаң, дөньяда күп авырулар беткән булыр иде инде. Аларның уллары Баһадур үскәч менә шундый кеше булыр, иншаллаһ, зур галим булыр, фәнни ачышлар ясар. Баш миен төзәтә торган машина да уйлап табар... Әтисе — күрә, апа-абыйлары ишетә-сөйләшә башларлар әле, Алла теләсә. Дөнья гел алга бара бит, фәндә хәзер әллә нинди ачышлар бар...»

Беренче класста берничә көн укуга, Баһадурны шунда ук икенче, аннан өченче, дүртенче классларга күчерделәр. Малай анда да озак утырмады, чөнки ул башлангыч класс балалары укыган бөтен нәрсәләрне инде күптән белә иде. Бу могҗиза баланы күреп, укытучылар да таң калдылар, чөнки ул алардан да күп белә иде. Шулай итеп, беренче класста укырга тиешле Баһадурны бишенчегә кертеп утырттылар. Малайны карарга журналистлар, радио-телевидение хезмәткәрләре, төрле белгечләр агыла башлады. Фәргать белән Гөлҗиһанның баһадир гәүдәле Баһадур уллары турында хәбәр бөтен шәһәргә таралды. Ә Баһадур исә боларга игътибар да бирмәде, ул, гомумән, хискә саранрак иде, аларны беркайчан чит кешеләргә күрсәтмәде. Ул башы-аягы белән физика, химия, математика, биология фәннәренә кереп батты, әйтерсең лә үзенә ни кирәкне тапты. Башкалар бер елда үзләштергәнне ул бер айда аңышты, бер айлыкны бер көндә өйрәнде. Шулай итеп ул өч елда сигез класс тәмамлады, тагы бер ел эчендә урта белемле булды. Унбер яшендә исә, урта мәктәпне гел бишкә генә тәмамлап, Иртәштәге технология институтына укырга керергә хәзерләнә башлады. Аны тагы бер тапкыр Мәскәүдән килеп чакырып карадылар, бу хикмәтле бала турында ишетеп, хәтта чит илләрдән дә чакырулар килә башлады. Андагы башны һәм акылны Япониядә атом бомбасы шартлаганнан соң кинәт күтәрелеп киткән технологик ачышлар белән чагыштырдылар. Татар баласындагы гадәттән тыш сәләтне радиациянең кешегә уңай тәэсире итеп күрсәтергә тырышучылар да булды. Бары тик Таһирҗан бабай гына моның Аллаһтан бер хәбәр, билге икәнлеген әйтте. Аларга төрле сынауларга әзер булып торырга кушты.

Шулай итеп, Баһадурның таныла башлаган бу еллары бөтен илгә, шул исәптән Иртәшкә дә хәбәрдарлык чоры килгән, ябык пәрдәләр бераз ачыла башлаган бер чорга туры

килде. Радио-телевидение көне-төне илдә булган ялгышлар, совет режимының җинаятьчел эшләре турында сөйләп тора. Дәүләт сере дигән нәрсә бетеп, Чернобыль фаҗигасе, атом, радиация турында халыкка дөрес мәгълүматлар чыга башлаган чорлар. Көньяк Уралдагы атом фаҗигасе турында да дөньяга хәбәрләр тарала башлаган вакыт. Бу хәбәрләр, әлбәттә, Баһадурга да килеп җиткән иде. Технология институтына керәм дип очынып йөргән җиреннән ул кинәт туктап уйга калды. Бүлмәсендә бөтенләй яңа төр китаплар күренә башлады. Ул башы-аягы белән радиобиология, атом, радиация турындагы хезмәтләргә кереп батты, шәһәр китапханәсендә бу темага ул укымаган китап калмады. Шулай ук Баһадур өстәлендә медицина буенча да бик җитди китаплар күренә башлады. Ул инде балачагындагы баш миен үзгәртә торган машина табу уеннан шактый ераклашкан, бөтен сорауларга да җавапны фәннән эзли иде.

Баһадур, төннәр буе китаплар өстенә иелеп, алардан җавап эзли — аның әтисе нидән сукырайган? Ул яңадан күрә башласын өчен, нишләргә кирәк? Телсез-чукрак апасы белән абыйсына ничек ярдәм итәргә, фәндә моңа җавап бармы? Чал чәчле карт галим кебек, ул китаплар өстенә иелгән. Һәм ул җавап тапмыйча туктамаячак. Ул хәзер дөньяга зур афәтнең кайсы яктан килгәнен белә, иң зур бәла аларның аяк астында икән. Кешелекнең башына җитәчәк фаҗига җир астында, ул яшәгән шәһәр астында. Ул боларга бала акылы белән дә барып җитте, ә олылар һаман шуны күрмиләр, бу хәлләргә ияләшкәннәр, аның белән көрәшеп тә тормыйлар. Ә кешелекне бик зур фаҗигаләр көтә бит...

— Әни, без бу шәһәргә ничек килеп эләктек? — дип сорады ул беркөнне, Гөлҗиһанны гаҗәпләндереп.

— Әтиең биредә хезмәт иткәндә авырып китте, ә мин, аны эзләп, бирегә килдем, — диде ул, улының күзләренә туры карап. — Аннан биредә яшәп калдык.

— Ә сез биредә нәрсә эшләнгәнен белә идегезме соң?

— Ул вакытта бөтен нәрсә дәүләт сере иде бит, улым, бүгенге кебек ачык сөйләмиләр иде. Әмма халык барыбер чамалый иде инде, биредә атом бомбасы ясаганнарын беләләр иде.

— Ә монда үтергеч радиация чыгып ятуын, җир астында һәм өстендә миллиардлаган микъдарда атом калдыклары саклануын беләләр идеме соң кешеләр? Шуның аркасында үзләренә үлем куркынычы янаганын беләләр идеме?

Бу сораулар артык җитди иде. Гөлҗиһан үзе дә гомер буе шушыларга җавап эзләде, халыкның авыруы һәм кырылуы аны шуңа этәрде. Ә бу бала нигә болар белән кызыксына икән соң?

— Юк, улым, халык анысын ук белми иде, — диде Гөлҗиһан. — Хәзер дә белмәүчеләр күп әле. Иртәш турында бик язмыйлар бит, һаман Чернобыльне генә сөйлиләр. Ә монда шартлау Чернобыльгә караганда да көчлерәк булган.

Боларны ишетеп, Баһадур урыныннан торып йөреп килде. Уникенче яше белән генә барса да, ул олылар кебек зур гәүдәле, эре сөякле иде, идәнгә басканда, паркет такталар шыгырдап тора. Ул бүген агарынып, арып киткән кебек, яшь гәүдәсе сыгылып килгән, күзләрендә нindидер газаплы сагыш бар. Гөлҗиһан улы өчен гел борчылып, анализларын биреп тора, соңгы вакытта аның канында шикәр артканлыгын белеп, ул хафага төште. Шуңа күрә улының артык борчылуын, бу мәсьәләләрдә тирән керүен бер дә теләми. Әмма Баһадурның үзе куйган сорауларга җавап алмый туктамаячагын яхшы белә ул.

— Улым, син нигә боларга кереп киттең соң әле? — диде Гөлҗиһан иплән кенә. — Син бит техник вузга барырга җыена идең.

— Бүген нәрсә иң әһәмиятле, нәрсә иң кирәге, мин шуның белән шөгыльләнәм, әни, — диде ул, үзенә хас турылык белән. — Бүген иң әһәмиятлесе — дөньяның куркынычсызлыгы, кешеләрнең сәламәтлеге. Калган барысы да вак нәрсәләр. Ничек кешеләр шушы фикергә килми — мин аңламыйм...

— Ә син ничек бу фикергә килдең соң, улым?

— Мин әтинең, туганнарымның авыруларына игътибар иттем. Синең авыруыңа. Бөтен Иртәшнең, Караболакның үлем чигендә торуына. Унбер яшьтән үземнең анализлар шундый булуга. Һәм мин шушы хәлләргә җавап табарга тырыштым. Һәм таптым. Боларның барысына да атом комбинаты, аннан таралган радиация гаепле. Монда яшәп, исән калып булмый, әни. Гомумән, бу тирәдә исән калып булмый. Ничек кешеләр шуны аңламый, атом бомбасы өстендә нәрсәгә өметләнеп яшиләр — белмим.

Улының бу сүзләре Гөлҗиһанның үзенә карата да үпкәшелтә булып яңгырады кебек. Һәм аңа тагы да куркыныч булып китте. Әйе, элек белмәсәләр, хәзер беләләр монда нәрсә икәнен. Ә һаман яшәп яталар. Чөнки Караболакта да шушы хәл, Чиләбе үзе дә шушындыйга әйләнеп бара. Бөтен илҗир агуга батты. Гөлҗиһан боларны аңлауга әкренләп, бөтен гомере буенча килде, ә улы әнә барысын да берьюлы белгән. Һәм фаҗиганең никадәр зур булуын да кинәт аңлаган. Һәм, әлбәттә, ул бу хәлләр белән килешә алмый, аларга ияләнергә теләми.

— Ә нишләргә соң, улым? — дип сорады Гөлҗиһан, үз сорауларына җавап таба алмыйча. — Боларны мин үзем дә

беләм хәзер, кешеләргә дә шуны аңлатам. Әмма кешеләр бу хәлләргә ияләнгәннәр инде, тормышларын шул «Маяк»тан башка күз алдына китерә алмыйлар. Әйтерсең лә туганда ук атом бомбасы кочаклап туганнар.

— Әгәр Иртәштә сакланган миллиардлаган кюри атом калдыклары шартласа, әгәр «Маяк»та берәр зур авария булса, дөньяның исән калуы икеле, әни. Без бөтен дөньяга, кешелеккә куркыныч яный торган урында яшибез икән. Менә мин шуларны аңладым һәм калган барысы да әһәмиятсез нәрсәләр булып калды.

— Бәлки, әтиең белән киңәшеп, моннан башка урынга күчәргә кирәктер, улым? — диде Гөлҗиһан, бу сүзләрдән гаҗиз булып.

— Без барыбыз да тамгалы инде, әни, — диде Баһадур, Гөлҗиһанны сискәндереп. — Кая барсак та, бу атом тамгасы безнең белән күчәчәк. Мең генә түгел, миллион еллар буе нәселне җимерә торган тамга бу. Бу тамга хәзер Иртәштә, Караболакта гына түгел, бу тирәдән меңнәрчә чакрым ераклыкта яшәүчеләргә дә сугылган. Бөтен илгә таралган. Без барыбыз да хәзер үзебез атом чыганагы, нурланыш чыганагы булып торабыз. Ягъни без хәзер башкаларга да шушы авыруны таратабыз. Бөтен ил хәзер бер-берсен агулый, шуңа миллионлап үләләр. Ил башында торучылар нигә моның төбенә төшеп карамыйлар, нигә ашыгыч рәвештә бу үлем комбинатларын ябып куймыйлар, нигә бөтен көчләрен кешене коткаруга бирмиләр? Менә шушы сорауларга җавап таба алмыйм мин, әни.

Боларны ишеткәч, Гөлҗиһан бөтенләй югалып калды.

Улы сөйләгәннәрнең күбесен ул инде үзе дә белә иде, әмма Баһадур бу нәрсәләрне артык фаҗигале рәвештә кабул итә кебек тоелды аңа. Әйе, Иртәштә дә, Караболакта да хәл начар, әмма бу бит әле дөньяның бетүе дигән сүз түгел. Илдә зур галимнәр, белгечләр бар, алар да уйлыйлардыр бу хакта, берәр чарасын тапмый калмаслар. Ә баланы бу хәтле куркыныч уйлардан бераз арындырырга кирәк, югыйсә аның башына сугуы мөмкин. Гәүдәсе зур булса да, барыбер бала бит әле ул, психикасы да ныгымаган. Боларны ул гына хәл итә алмый, шуны яхшылап аңлатырга кирәк. Бәлки әле атасы да иплән кенә сөйләшеп карар. Иң мөһиме — аны хәзергә Иртәштән алып китәргә кирәк. Авылда әнисе, Таһирҗан бабасы да күптән көтә аларны, бәлки, бу көннәрдә җыенып Караболакка да кайтып килерләр.

— Бу бер көндә генә җавап таба торган нәрсәләр түгел шул, улым, — диде Гөлҗиһан, ничек тә улын юатырга тырышып.

— Безнең вакытыбыз аз калды шул, әни, — диде Баһадур, әнисен сискәндереп. — Минем уйлавымча, иң беренче

«Маяк»ны туктатырга, ябарга кирәк, ул эшләп торганда, монда беркем дә исән кала алмый.

«Маяк»ны туктатырга? Моңа кем ирек бирсен, шәһәр халкы үзе үк каршы чыгачак моңа! Чөнки бөтенесенең тормышы шул комбинат белән бәйләнгән, ул булмаса, халык эшсез калачак. Әмма бу балага моны ничек аңлатасың? «Маяк» артында дәүләт үзе тора бит, атомчылар тора, хәрби көчләр тора. Алар бу хәлгә беркайчан ирек куймаячаклар, хәтта ярты дөньяның көле күккә очса да.

Гөлҗиһан улына боларны әйтеп тормады, ул акыллы бала, үзе дә аңлар дип уйлады. Аның хәзер ничек тә улын бу сөйләшүдән читкә алып китәсе, борчулы уйларын алыштырырлык өмет, шатлык бирәсе килә иде.

— Картнәең, Таһирҗан бабаң да бик чакыра, бу көннәрдә Караболакка кайтып киләсе булыр, улым, — диде ул, сүзне читкәрәк борып. — Анда Япониядән галимнәр килгән икән, авылны бик өйрәнәләр, ди.

Бу турыда ишеткәч, Баһадурның йөзенә шатлык иңде, кайгылы күзләре яктырып китте.

— Чынлапмы, әни?! — диде ул, балалар кебек куанып. — Караболакны бик сагындым мин, картнәйне, Таһирҗан бабайны бик күрәсем килә. Японнарның анда булуы да бик кызык. Алардан сорыйсы нәрсәләрем бар әле минем.

Шушы кечкенә генә шатлык та зур кайгыларны басып китте кебек...

Адәм баласына, дөнья кайгыларыннан арынып тору өчен, шәхси бәхете, өмет-хыяллар да кирәк шул. Караңгылыкны таратырга яктылык кирәк. Караболак, туган авыл, туган нигез, нәсел-ыру алар өчен әнә шундый яктылык, шатлык чыганагы иде. Хәтта шушы хәлендә дә ул барыбер туган туфрак булып кала иде.

Караболак халкы исә хәзер һәр көн Гөлҗиһанның үзеннән бер яңа хәбәр, ярдәм көтә. Чиләбедән килгән җавапны ул авылга алып кайтып укыды, халык бу җаваптан бик нәфрәтләнде. Ничек инде Караболак ул чакта зарар күрмәсен, бөтен авыл үлеп бетә бит инде шул зәхмәттән! Гөлҗиһан тагы Мәскәүгә хат язды, депутатлар да, министрлар да, прокурорлар да — берсе дә калмады. Ул яза торды, ялган, ясалма җаваплар килә торды. Имеш, Караболак күптән инде күчерелгән, ул юк. Имеш, Караболак радиациядән бернинди дә зарар күрмәгән, шуңа күрә махсус ярдәм дә була алмый. Мәскәү — Чиләбегә, Чиләбе Коншакка төртеп күрсәтте, Гөлҗиһанның хатларын, мөрәҗәгатьләрен шулай ике арада типкәләп йөрттеләр, беркем дә Караболакка ярдәм итәргә ашыкмады, барысы да, бөтен көчләрен биреп, Караболакның радиациядән зарар күрмәвен исбатларга алындылар.

Бу юл белән барып чыкмаганны күргәч, Гөлҗиһан Мәскәү һәм Чиләбенең хокук яклау оешмаларына, экологларына чыгып карады. Һәм шунда ук Караболакка игътибар артты — анда бер-бер артлы чит ил белгечләре, табиблар, журналистлар килә башлады, Караболак фаҗигасен алар өйрәнергә алындылар. Әмма хакимият башында утыручыларга бу хәл ошамады, алар дәүләт серен ачалар дигән иске сылтау белән чит ил белгечләрен Караболакка якын җибәрмәскә тырыштылар. Бу эшләрне оештырып ятучы Гөлҗиһан икәнен белгәч, аны эшеннән алу белән яный башладылар. Фәргатькә дә эшендә басым башланды, аны да өйгә куып кертергә, җәмәгать эшләреннән читләштерергә тырыштылар. Ахрысы, Ткаченко командасы да йоклап ятмый иде, Гөлҗиһан һәр адымында үзен тикшергәннәрен, күзәткәннәрен, хатларын ачып укуларын, телефоннарын тыңлаганнарын сизеп алды. Ул үзенең нинди куркыныч юлга кереп баруын аңлап та бетерми иде, ахрысы... Аның уенда бары тик Караболак язмышы, авыл халкына ярдәм итү иде. Ә дәүләтнең төп максаты — бу эшләрне читкә чыгармау, дөреслекне һаман җир астында калдыру. Гөлҗиһан, үзе дә сизмәстән, Россия хөкүмәте белән тигезсез көрәшкә чыккан иде.

Иртәштә Караболак авылыннан шактый кеше яши һәм аларның барысы да диярлек 1957 елгы шартлаудан зарар күргән, колхоз кырларында радиация пычрагын чистартуда катнашучылар иде. Шул исәптән Гөлҗиһан үзе дә. Һәм алар «Маяк»ка каршы суд эше кузгатырга булдылар, үзләрен ликвидатор итеп тануны дәгъва иттеләр. Чөнки Гөлҗиһан аңлады — хатлар язып кына бу мәсьәләләрне хәл итеп булмый иде. Димәк, суд юлы белән үзләренең радиациядән зарар күрүләрен исбатларга кала. Ә моңа бары тик Караболакның да радиациядән зарар күрүен исбатлап кына ирешергә мөмкин булачак иде. Бу эштә алар Фәргатьне адвокат итеп алдылар һәм эшкә керештеләр.

...Әнисенә сиздермәскә тырышса да, көннән-көн көчәя барган баш авыруы Баһадурны тәмам гаҗиз итте. Шуңа күрә ул әнисенең Караболакка кайтып килү тәкъдимен бик сөенеп кабул итте. Бары тик шунда, Таһирҗан бабасы янында, Аллакүл чишмәсе буенда гына, Баһадур үзен дөньяда иң бәхетле кеше итеп хис итә. Ул анда бөтен җиһан белән кушыла, Аллакүл чишмәсенең бер тамчысына, Караболак өстендәге күкнең бер йолдызына әйләнә. Бары тик шунда, туган туфракта гына, Баһадур борынгы бабаларының кан авазларын ишетә, үзенең кемлеген таный, асылына кайта. Караболак тарихы, борынгы татарлар тормышы, Алып Ханнар нәселе турында аңа бабасы инде күп тапкырлар сөйләде. Баһадур үзендә шушы тарихи хәтерне йөртүенә куана, шушы ба-

һадир татар милләте вәкиле булуына горурлана. Әмма аның өчен иң мөһиме — Баһадурның туган туфрагы, нигезе, нәселе бар. Атомга каршы берүзе көрәшеп ята торган Караболагы бар.

Әнә хәзер дә ул әллә төшләрендә, әллә өнендә Баһадур каршына очып килә. Юк, бу Караболак түгел, Баһадур үзе аңа таба оча икән бит. Аста Иртәш күле, ап-ак каен урманнары җәелеп кала, каршыга исә Урал таулары, Караболак йөгерә. Баһадур исә тәкъдире каршына оча.

Тукта, бу бит Баһадурның башы шулай әйләнә. Тимер кыршау белән тарттырып куйган кебек кыса, авырта. Баһадур, әнисе ишетмәсен өчен, канатканчы иреннәрен тешли, әкрен генә урынына чүгә. Аның тәне башта авырая, басыла, аннан авырлык та, тән үзе дә сизелми башлый — Баһадур караңгы бушлыкка ава. Дөньясын басып киткән караңгылык бераз тарала төшкәч, Баһадур биредә үзенең ялгыз түгеллеген күрә. Әнә Уралтаудан тезелешеп зур-зур кешеләр төшеп килә. Алар шундый озыннар, тау түбәсендәге ташларны куллары белән генә үрелеп алалар... «Болар синең борынгы туганнарың — Алып бабаларың, алар сине көтә», — дип пышылдый Баһадурга эчке тавыш. Аннан Баһадур тау итәге буйлап тезелеп киткән зур-зур шәһәрләрне күрә, алар дала буйлап сибелгәннәр. Аннан Баһадур атка атланган гайрәтле ирләрне, мәгърур татар ханнарын, алар идарә иткән ил-җирләрне күрә. «Болар синең борынгы туганнарың, алар сине көтә», — дип пышылдый эчке тавыш. Аннан Баһадур Караболак буйларын, Аллакүл чишмәсен, тау куышын, борынгы курганнарны күрә. Күз алдыннан тезелешеп ап-ак карт-карчыклар, гайрәтле ирләр, сылу татар хатыннары, төркем-төркем балалар үтә. «Болар синең нәселең, алар сине көтә», — дип пышылдый Баһадурга эчке тавыш. Аннан Баһадур әнисенә бик нык охшаган карт белән карчыкны күрә. Алар: «Без синең әби-бабаң, без дә сине көтәбез», — диләр, ниндидер нурлы болыннан Баһадурга кулларын изиләр, аны чакыралар. Аннан күк экранында Нәбиулла карттаеның йөзе чагылып үтә, ул да оныгын үз янына чакыра. Малай берәм-берәм Якуп бабасын, Хәбибулла абыен, үзе беркайчан да күрмәгән башка туганнарын шул болында күрә. Алар барысы да аны көтәләр, аны чакыралар иде. Малайның үзенең дә алар янында каласы килә, чөнки анда дөньяда булмаган рәхәтлек, чисталык һәм яктылык. Ул көмеш нурга чумып утырган яшел болынлыклар, челтерәп аккан татлы чишмәләр, ул пакь, яхшы ризыклар. Әмма иң мөһиме — биредә бер генә бәхетсез кеше дә юк, монда кайгы-хәсрәт тә юк, авыру да юк. Биредә кешегә авырлык китерә торган бер генә нәрсә дә юк. Монда барысы да кешегә яхшы булсын өчен эшләнгән, бө-

тен дөнья сөенеч-шатлыктан һәм нурдан гына тора. Шуңа күрә монда барысы да бәхетле.

Баһадурга астан әти-әнисе, туганнары кул болгый, аның тизрәк җиргә төшүен телиләр, ялваралар. Ул теләр-теләмәс кенә Караболакның кара урман кебек шаулап утырган зираты өстенә төшә. Ә анда аны йөз яшьлек Таһирҗан бабасы көтеп тора икән. Ул ап-актан киенгән, йөзеннән нур балкып тора. Ул Баһадурны кулларыннан ала да Аллакүл буена алып китә. Һәм аңа дөньяда булган иң зур серне ача. Ничек итеп кешелекне саклап калырга, ничек бәхетле булырга, ничек бу бәла-казалардан котылырга? «Бу — дәүләт сере түгел, Аллаһ сере, — ди Таһирҗан бабасы, оныгы өстенә иелеп. — Син аны белеп китәргә тиешсең, улым». Һәм Таһирҗан карт аңа җиһан серен ача. Бу сер алдында Баһадур үзе дә, аны чорнап алган дөнья да, алар өстенә килгән кайгы-хәсрәтләр дә бик кечкенә, әһәмиятсез булып кала. Моңа кадәр шушыларны белмәвенә Баһадур гаҗәпләнә, бөтен гыйлеменең шушы бер сергә тормавын аңлый. Әмма ул инде яңадан күккә дә күтәрелә алмый, җирдә дә кала алмый икән. Баһадур үзенең җир белән күк арасындагы вакытта яшәвен аңлый, бу чорының вакытлы гына булуын белә. Ул җиргә шушы серне алу өчен генә кайткан, хәзер инде яңадан күккә, инде мәңгелеккә китәргә тиеш...

Баһадур авырлык белән генә күзләрен ачты һәм янында тезләнеп торган әнисен күреп аптырап китте. Әнисе куллары аның маңгаена куйган, зур яшел күзләре яшь белән тулган иде.

— Авырыйсың, ахры, балам? — диде ул, башын улының күкрәгенә куеп. — Баядан бирле янында утырам, бик саташасың. Һаман әби-бабаларыңны чакырасың, Таһирҗан бабаң белән сөйләшәсең.

— Ә мин аларны төшемдә күрдем, — диде Баһадур, нәрсәнедер исенә төшерергә тырышып. — Караболакка кайчан кайтабыз, әни? Миңа Таһирҗан бабайны күрергә кирәк, бик тиз кирәк...

— Үзем дә шуны әйтергә кергән идем, улым. Авылдан Таһирҗан бабаң шалтыратты, Баһадурны алып, тиз арада кайтып җитегез, диде. Әллә авырып киттеме икән дип курыктык, йөз яшьтә бит инде ул, теләсә кайсы вакытта китеп барырга мөмкин...

Моны ишетеп, Баһадур урыныннан сикереп торды.

Таһирҗан бабасы аның өчен дөньяда иң кадерле кешеләрнең берсе иде. Ул аны Ак бабай дип йөртте, аның кулларына тотынып, бөтен Караболакны, Аллакүл буйларын йөреп чыкты. Таһирҗан бабасы аңа беренче догаларны, татарча шигырьләр өйрәтте, авыл тарихын, нәсел тарихын җен-

текләп яздырды. Таһирҗан бабасы аңа чишмә суларының серен ачты, Караболак болынында үскән чәчәкләрне танырга өйрәтте, җәйге яңгырларның, кышкы бураннарның телен аңлатты. Ул дөньяны, Караболакны Таһирҗан бабасыннан башка күз алдына да китерә алмый иде. Ә төшендә ул аңа ниндидер сер ачты. Шул сере артыннан хәзер үзе Караболакка кайтырга тиеш Баһадур...

— Улым, хәлең авылга кайтырлыкмы соң, — диде әнисе, аның агарып калган йөзенә карап. — Башың эссе кебек тоелды, юлга чыгарлыкмы соң?

— Хәлем әйбәт, әни, — диде Баһадур кыска гына. — Ә авылга кайтырга кирәк. Таһирҗан бабай юкка чакырмас.

Ул төнлә күргән сәер төшен әнисенә сөйләп тормады, чөнки анда Таһирҗан бабайдан кала, барысы да үлгән кешеләр иде. Һәм алар барысы да Баһадурны көтүләрен әйттеләр. Баһадурның үзенең дә алар янында каласы килде, чөнки анда бик тыныч, рәхәт иде. Әмма әти-әниләре, туганнары аны җиргә чакырып төшерделәр. Малай сизә, бәлки, озакка да түгелдер.

Фәргатьнең ныклап судка әзерләнәсе бар иде, ул бу юлы авылга кайтып тормаска булды. Ул хатыны белән улына үзенең фатихасын бирде. Гөлҗиһан белән Фәргать иртәнге якта ук Караболакка кайтып киттеләр. Баһадур үзенең бу шәһәрдән инде мәңгегә чыгып киткәнен белми иде әле. Ул бу атом базына адашып килеп кергән дала-тау кошы кебек иде. Һәм ул мәңгелеккә үз иленә, үз җиренә кайтып бара иде...

Таһирҗан карт аларны авыл башына ук чыгып каршы алды. Аны аяк өстендә күргәч, Гөлҗиһан белән Баһадур бик сөенештеләр. Таһирҗан карт яраткан оныгын бик озак күкрәгенә кысып торды. Гөлҗиһан бабасының бер дә картаймавына игътибар итте, ул, киресенчә, яшьлек ягына таба үзгәреп бара иде. Битләре балаларныкы кебек шоп-шома, кулларында да җыерчык заты юк, бабасының гәүдәсе төз, адымы җиңел иде.

— Бер-бер хәл булмагандыр бит, Таһирҗан бабай? — диде Гөлҗиһан, инде әнисе өчен куркып. — Әллә әнигә берәр нәрсә булдымы?

— Барыбыз да исән-сау, Аллага шөкер, — диде Таһирҗан карт, тизрәк аны тынычландырып. — Менә Баһадур улым кирәк булды әле. Җәй үтеп бара, аның әле быел авылга кайтканы юк. Үземнең дә аңа сүзем бар аннан, авылга японнар килде, рәтләп тел белүче юк. Баһадурның чит телләр белүен искә төшердек тә аны чакырырга булдык менә.

Гөлҗиһан җиңел сулап куйды...

Аллага шөкер, барысы да исән-сау, барысы да яхшы икән.

Улын авыл халкына кирәк булганга чакырганнар икән. Гөлҗиһан моңа сөенде генә, ул малаеның кешеләргә кирәк булуын, ярдәмчел булып үсүен тели иде. Караболакны онытырга, ташларга тиеш түгел ул, әти-әнисеннән соң да авыл халкына кулыннан килгәнне ярдәм итәргә тиеш. Таһирҗан бабай белән бергә булуы да Баһадур өчен яхшы булыр, бераз җанын тынычландырыр, уйлары башка якка кереп китәр.

Картның Аллакүлгә суга баруы икән, ул аларны да үзе белән чакырды. Әмма Гөлҗиһанның тизрәк әнисе янына кайтасы, аны күрәсе килә иде. Шуларны әйтеп, ул авыл ягына ашыкты, Таһирҗан карт белән Баһадур исә Аллакүлгә таба атладылар. Гөлҗиһан карап калды — алар, бер-берләренә сыенып диярлек, кыр юлы буйлап китеп бардылар. Баһадур янында Таһирҗан карт үзе бала кебек күренә. Таһирҗан бабасы аны үз оныкларыннан да артык күреп ярата шул, үзендә булган бөтен гыйлемне, тормыш тәҗрибәсен аңа биреп калдырырга тели кебек... Һәм хикмәтне дә.

Биташ күле аларны рәхәт салкынлыгы, ярларында җемелдәп яткан зәңгәр балчыгы белән каршы алды. Баһадур исә тизрәк тау куышыннан бәреп чыккан чишмә янына ашыкты, салкын су белән бит-кулларын юды, чәчләрен чылатты. Һәм, ни хикмәт, баядан бирле авыртып интеккән башы сафланып калды, сызланулары юкка чыкты. Малай, ташка тезләнеп, чишмә суы эчте, эчкән саен үзендә көч-гайрәт артуын сизде, әйтерсең лә ул әкиятләрдәге каһарман иде. Бабасы аны моңсу гына елмаеп күзәтте, чөнки ул аның бу дөньяда кадерле кунак кына икәнлеген белә иде...

Шулай бераз тын алгач, мәгарә күләгәсенә барып утырдылар. Баһадурның элек тә бирегә килгәне бар иде. Һәм бүген төшендә дә ул шушы Аллакүлне күрде, Таһирҗан бабасы аңа шунда бер сер ачкан иде.

— Мин сине бүген төшемдә күрдем, бабай, — диде ул уйчан гына. — Шушы Аллакүл буенда син миңа ниндидер сер ачтың.

— Аллаһ сере иде ул, улым, җиһан сере, — диде Таһирҗан карт, күл өстенә карап. — Ничек бу дөньяны, үз-үзеңне коткарырга.

Баһадур аптырап китте, бабасы аның нинди төш күргәнен каян белә икән? Ул бит аңа әле боларны сөйләмәде?

— Ә син каян белдең, бабай, бу төш турында? — диде ул, тагы аптырап.

— Чөнки мин дә бүген төнлә нәкъ шундый төш күрдем, улым, — диде Таһирҗан карт. — Шуңа күрә сине тизрәк чакыртып кайтарттым.

— Мине анда көткәннәрен дә күрдеңме?

— Күрдем, улым. Бөтен әби-бабаларны, борынгы туган-

нарны күрдем. Урыннары җәннәттә булганны белеп сөендем. Сине дә шунда көткәннәрен белдем.

Баһадур бабасыннан башка берни дә сорамады. Ул инде барысын да аңлаган иде.

Алып Ханнар нәселен дәвам итүче бу ике ир-атның башка сөйләшәсе җитди сүзләре бар иде. Һәм аларга боларны әйтеп өлгерергә кирәк иде. Алар икесе ике чор кешеләре булсалар да, аларда бер нәсел каны ага, бер иман нуры балкый, алар бер телдә аңлашалар иде. Таһирҗан карт дөньяны җаны белән тойса, Баһадур аны акылы белән ача.

— Иннә лилләһи вә иннә илайһи раҗигуун, — диде Таһирҗан карт, төш турында сөйләшүгә йомгак ясап.

— Әйе, барыбыз да аннан килгән һәм яңадан Аллаһка кайтачакбыз, — диде Баһадур, бабасының сүзләрен җөпләп.

Алар, гомер иткән ике аксакал карт кебек, сабыр гына сүз башлап җибәрделәр. Таһирҗан карт белә иде — бу балага әүлиялар зирәклеге бирелгән, әмма ул бу дөнья өчен түгел. Ул дөньяга гыйбрәт өчен генә яратылган һәм ул тиздән китәчәк. Чөнки бу дөньяга әүлиялар кирәкми.

— Мин барысын да беләм, бабай, — диде Баһадур, аның уйларын күргәндәй. — Мин тиздән китәм. Әби-бабалар янына. Әүлиялар, пәйгамбәрләр янына. Миңа анда яхшы булачак.

— Беләм, улым, шуңа күрә чакыртып та кайтардым. Анда әзер барырга кирәк. Шуның өчен чакырдым...

Аларның икесендә дә әүлиялар акылы иде.

Үзләре турында алар барысын да беләләр һәм моңа әзер иделәр.

Аларны, үзләреннән дә бигрәк, ил-җир тормышы, Караболак язмышы борчый иде. Чөнки алар китә, ә ил, милләт кала.

— Караболакка нәрсә булыр икән инде, бабай? — диде Баһадур, үзе турында сөйләшүгә нокта куеп. — Аларның барысында да атом тамгасы бит, нурланыш авыруы.

— Караболак халкы тереләй сират күпере үтә, улым, сынау үтә. Аллаһ безгә рәхмәтен дә, җәзасын да бирде. Рәхмәте — безнең һаман ил-авыл булып яшәвебез, җәзасы — шушы чирләребез.

— Ә җәзасы нигә, бабай? — диде Баһадур, тормышның бу нечкәлекләрен әле аңламыйча.

— Без, татарлар, пәйгамбәрләр нәселен дәвам итүче халык, улым. Туфаннан исән калган Нух пәйгамбәр варислары без. Шуңа күрә безнең яшәвебез дә пәйгамбәрләр тормышына лаек булырга тиеш иде. Мең еллар буе ул шулай булган да. Татарлар иксез-чиксез җирләрдә зур-зур дәүләтләр, илләр тотып яшәгәннәр. Әмма соңгы йөз елда халык динне оныта башлады, Аллаһ кушканча яшәмәде, улым... Күпләр,

дөнья куюга алданып, Аллаһны онытты, намазларны ташладылар, чит-ят гадәтләрне алдылар. Авылдан әкренләп иман качты. Шуннан соң Аллаһ бездән бәрәкәтне алды, шушы бәлаләрне сәбәпче итте. Әмма күпләр моны һаман аңламый әле. Әнә авыл уртасында мәчет тора, ә халык йөрми. Көнгә биш вакыт намазны берничә карт кына укыйбыз. Гыйбрәт ала алмады халык бу бәладән. Иманга кайтмады, намазга басмады. Югыйсә анда баруга беренче соралачак нәрсә намаз булачак бит, намаз, улым. Атом да түгел, радиация дә түгел, рак та түгел, ә намаз булачак. Чөнки мондагылар барысы да монда кала, ә анда бары тик намаз һәм изге гамәлләр генә бара. Һәм шулар соралачак та.

— Миннән дәме? — диде Баһадур, тетрәп китеп.

Чөнки аның беркайчан да бу турыда уйлаганы, бу юнәлештә фикерләгәне юк иде. Ул дөньяның күп телләрен өйрәнде, физика, математиканы җиңде, фәнне, техниканы үзенә буйсындырды, радиобиологиягә, медицинага үтеп керде, үзенең ачышларын ясады. Әмма Баһадурның беркайчан да үләчәк нәрсә буласы турында уйлаганы юк иде. Аңа әзерләнгәне дә юк иде. Аның үлем турында уйлаганы да юк иде.

— Син хәзергә бала өммәтендә, улым, әмма инде бу чикне үтеп барасың. Кайчан Аллаһ каршына басасыбызны беребез дә белми, шуңа күрә сиңа да әзерләнергә кирәк... Барыбызга да әзер булып торырга кирәк... Анда әзерлексез барсак, монда күргән газапларыбыз тәмуг газаплары алдында бик кечкенә булып калачак...

Баһадурга кинәт бик эссе булып китте, утлы кайнар җил битенә китереп бәргән кебек булды. Аның тагы башы әйләнә башлады, авызы кипте, теле әйләнмәс хәлгә килде. Ул тизрәк битен чишмә суына тидерде, берничә йотым эчеп тә куйды. Бабасы сөйләгәннәр аның бөтен җанын тетрәткән иде, һәм болар барысы да дөрес иде. Баһадур, үзеннән дә бигрәк, әти-әнисе, туганнары өчен ут йотты, чөнки бабасы әйткәннәр аларга да кагыла иде. Иртәме-соңмы бөтен нәсел, бөтен Караболак китәчәк һәм Аллаһ каршына барып басачак. Һәм алардан да шушы ук нәрсәләр соралачак.

Баһадурның күз алдында утлы очкыннар сикереште. Аллакүл мәгарәсе кинәт юкка чыкты һәм Баһадур алдында җиде кат җир ачылып китте. Бу алар яшәгән Иртәшнең асты иде. Өстә — шәһәр, аста — атом заводлары, тагы да аста, тирәндә — утлары үкереп торган коточкыч тирән чокыр. Тирә-якка кара кисәүләр атыла, ялкын телләре өскә сикерә. Баһадурның бара торган юлын шушы утлы чокыр каплаган, бер якка да үтәрлек түгел. Алда нурлар чәчеп торган яшел болынга шушы утлы чокыр аша салынган тар күпер аша гына үтәргә мөмкин икән. Ә ул күпер — кылдан нечкә, кы-

лычтан үткен. Баһадур алдыннан баручылар берәм-берәм шул утлы чокырга тәгәрәп төшәләр. Ул бу күпергә керергә курка, әмма теге якта, нурлы болында, кулларын болгап, аны ерак туганнары, әби-бабалары көтеп тора. Баһадур, тәвәккәлләп, утлы күпергә аяк баса. Менә ул аның буенча берничә адым атлый, менә күпернең уртасына җитә, барасы әле шактый ерак, ә аста утлы җәһәннәм кайный. Баһадурның башы әйләнә, тыны бетә, ул шулчак әнисенең моңлы тавышын ишетә. Бу тавыш аңа көч-дәрт бирә, алга чакыра. Инде тагы беттем, инде башка бара алмыйм дигәндә, ерактан әтисенең тавышы ишетелә, ул да улы өчен изге теләкләр тели, дога кыла. Җәһәннәм уты табаннарны яндыра башлаган бер мизгелдә, малай Таһирҗан бабасының тавышын ишетә, ул аңа күперне үтеп нурлы болын ягына чыгарга ярдәм итә. Болыннан аның каршына туганнары йөгереп килә. Инде алар белән мәңгегә кавыштым, күрештем дигәндә, тагы Таһирҗан бабасының тавышы ишетелә.

— Сиңа анда иртәрәк әле, улым, — ди ул.

Бу тавыштан Баһадур сискәнеп күзләрен ача һәм үз өстенә иелгән Таһирҗан бабасын күрә. Бабасы ниндидер дога укый һәм Баһадур өстенә шифалы сулышын өрә.

— Курыкма, улым, Аллаһ сине ташламас, — ди ул, аның битләреннән сыйпап. — Боларның барысын да күрсәтеп, ул сине сыный, каршына килүеңне көтә. Шуңа әзерли. Уттан ничек котылырга кирәген өйрәтә.

— Ул ут коточкыч куркыныч, бабай, — диде Баһадур, башын калкыта төшеп. — Үкереп, зур-зур утлы кисәүләрен чәчрәтеп яна. Аның өстендә бик нечкә, тар күпер бар, аннан күп кешеләр үтә алмый, аска тәгәриләр. Мин күперне чыгып җиттем, әмма хәзергә теге яктагы болынга керә алмадым. Синең тавышыңны ишеттем. «Сиңа анда иртәрәк әле, улым...» — дидең.

— Ул яктаниләр күрдең, улым?

— Бөтен ерак туганнарны күрдем. Әби-бабайларны күрдем. Бөтен яхшы кешеләрне күрдем. Минем дә алар янына чыгасым килде. Әмма нидер тотты. Мин әле алар янына барырга әзер түгел идем. Миңа әзерләнергә кирәк икән, бабай.

— Сиңа намазга басарга кирәк, улым. Аллаһ сиңа намаз укырга вакыт җитүен хәбәр иткән. Моны хәзер син үзең дә аңладың инде.

— Әйе, бабай, — диде Баһадур уңайсызланып. — Әмма мин белмим бит. Әни һәм син өйрәткән аерым догаларны беләм, ә намаз укыганым булмады.

Әйе, Баһадурның теле дога белән ачылган иде. Ул сөннәт белән туган бисмиллалы бала иде: әти-әнисе белән Караболакка бөтен гаетләргә кайтты, гел Таһирҗан бабасы янында

мәчеттә булды, әмма дингә тирәннән кереп китә алмады. Аны бөтенләе белән дөнья гыйлеме басты. Әти-әниләрен дөнья мәшәкате баскан кебек. Ә дөньяның чиге бар икән. Ул чикне үткәч, башка нәрсәләр кирәк икән.

— Син бик зиһенле бала, улым, тиз өйрәнерсең, — диде Таһирҗан карт, аның аркасыннан сөеп. — Иң мөһиме — синең шушы нәрсәләрне аңлавың. Өлгерүең. Шушы юлга басарга теләк белдерүең, ниятең. Калганына Аллаһ ярдәм итәр, иншаллаһ.

Карт белән онык Караболак ягына таба атладылар.

Аллакүл чишмәсе аларны дога кылып озатып калды.

Бу җирдә беренче Алып Адәм намаз укыган таш алар өчен озаклап гыйбадәт кылды.

Күлдәге балыклар адәм балалары өчен тәсбих тартты, яр буендагы камышлар сәҗдә кылды, зәңгәр күк исә боларның барысына да Аллаһ каршында шаһәдәтлек китерде. Чөнки тагы бер адәм баласы изге юлга баскан, иманга килгән иде.

Караболак аларны тузанлы урамнары, чәчәкле тәрәзәләре, кычытканлы тыкрыклары белән каршы алды. Менә ничә еллар инде авылда төзелешләр бик аз бара, яшьләрнең аякка баскан берсе шәһәргә китеп бара, Караболакта исә карт-карчыклар гына кала иде. Кайчандыр гөрләп торган мәктәп тә инде сүнеп, җиргә сеңеп бара, заманында меңгә якын бала укыган Караболак мәктәбенә беренче класска барырга бала юк. Теге елларда ук таштан салып куйган мәдәният йорты да күп вакыт буш, анда инде, Гөлҗиһаннар заманындагы кебек, татар җырлары яңгырамый, шәһәрдән яшьләргә ияреп кайткан чит көйләр хакимлек итә. Клуб каршындагы мәчет тә күп вакыт буш, елына ике тапкыр, бары тик гает көннәрендә генә ул Караболакка кайткан халык белән тула. Меңьеллык борынгы Караболак күзгә күренеп сүнә, атом сазлыгына бата бара. Һәм шушы Караболак урамнары буйлап, бер-берсенә сыенып, алып гәүдәле үсмер малай һәм Хозыр Ильяс кебек ак бабай атлый. Соңгы өмет белән атлыйлар. Алар әле Караболакны уятырга, коткарырга омтылып карарлар. Әмма Караболак язмышын хәл итү Аллаһтан булыр...

Менә карт белән онык авыл башындагы Сәкәлин урамына таба борылалар, шау чәчәктә утырган бер йорт каршына килеп туктадылар. Кайчандыр гөрләп торган зур йортта Хәбирә карчык хәзер ялгыз гына яши, ире Нәбиулла да, каенатасы-каенанасы да күптән инде Караболак зиратына күчтеләр. Малайлар читтә, алар кайтса, елына бер генә кайта ала. Ә Гөлҗиһан, карчыкның бәхетенә, Иртәштә генә урнашып калды, атна саен булмаса да, ул аена берничә тапкыр Караболакка кайтып килә, карчыкның бөтен эшләрен башкарып китә. Бу юлы да әнә кайтканнан бирле җыя, юа, ашарга әзерли. Кар-

чыкның сөенеченә, оныгы Баһадурны да монда калдырып китә икән.

Алар кайтып кергәч, бергәләп утырып чәй эчтеләр. Аннан Таһирҗан карт мәчеткә, өйлә намазына әзерләнә башлады.

— Бабай, мин дә синең белән барам! — дип, урыныннан сикереп торды Баһадур, чәен дә эчеп бетермәгән килеш.

Гөлҗиһанның йөрәге рәхәт кысылып куйды.

Улының бу сүзләрен, бу фикергә килүен ул инде күптән көтә иде, әмма гел әйтеп торып ирексезлисе, диннән гайрәтен чигерәсе килмәде. Ә бабасы әнә, кайту белән, аңа ничек тәэсир ясаган. Ир балага ир кеше тәрбиясе, аның сүзе, үрнәге кирәк шул. Фәргать бу мәсьәләдә ярты кеше инде, ул дөм сукыр күзләре белән тормыш алып баруына да рәхмәт. Балага, бәлки, бу мизгелләрдә нәкъ шушы кирәктер, замана сорауларыннан арыган җанына тынычлык кирәктер. Ә ул тынычлыкны бары тик ислам дине генә бирә ала.

— Башта, мунчага кереп, госел коенып чык, улым, — диде ул йомшак кына. — Таһирҗан бабаң күрсәтер ничек икәнен.

Карт белән онык, әзерләнеп, мәчеткә чыгып киттеләр.

Улында ниндидер үзгәреш барын беренче булып ана кеше сизеп алды. Моңа кадәр күрелмәгән зур үзгәреш иде бу. Бала бөтенләй олыгаеп, җитдиләнеп калган. Иртәштәге кебек, әнисенә артык сораулар да бирми, җавап та эзләми, әйтерсең лә ул инде нәрсә эшләргә кирәген белә, барысына да җавап тапкан. Мондый вакытта аның янында әүлияга тиң Таһирҗан бабайның булуы да бик яхшы әле, ул Баһадурга иң кирәген әйтәчәк, төпле киңәш бирәчәк. Чөнки соңгы вакытта улы, уку, фән, техника, телләр дип, аннан атом мәсьәләсенә кереп китеп, кирәгеннән артык бәргәләнә, бетерәнә бит. Югыйсә аның балачак хыяллары, уеннары, үзе кебек дуслары да булырга тиеш бит. Ә ул һаман дөнья проблемаларын хәл итмәкче, беркем таба алмаган сорауларга җавап тапмакчы. Болай бит аның башына көч килүе дә бар, Гөлҗиһан андый балаларны күп күрде Иртәштә. Аллам сакласын, аның улы да шундый хәлгә кала күрмәсен. Таһирҗан бабай бик вакытлы чакыртып алды аларны, бераз ял итәр, башка нәрсәләр турында уйлар. Ә бу нәрсәләрне, атом проблемасын ул гына хәл итә алмый, аңа Гөлҗиһан белән Фәргатьнең генә дә көче җитми, алар кулдан килгәнне генә эшли алалар.

Караболакка кайтуына бик сөенде Гөлҗиһан, әмма аңа яңадан Иртәшкә кайтырга кирәк иде. Эшеннән дә сорап кына китте, судка да әзерләнәсе бар. Фәргать «Маяк» мәсьәләсендә Караболак кешеләренең адвокаты булса да, аңа бөтен кирәкле документларны, белешмәләрне Гөлҗиһан табыша, Гөлҗиһан эзләшә. Аларга бу көннәрдә ашыгыч рәвештә Чиләбегә барырга, архивлардан Караболакка бәйле белешмә-

ләрне эзләп табарга кирәк. Җитмәсә, соңгы вакытта Фәргать тә авырыбрак тора, анализлары яхшыга таба түгел. Шуңа күрә, улын авылда калдыруга, Гөлҗиһан тизрәк Иртәшкә ашыкты. Улының гомере санаулы гына көннәр калуын ул күз алдына да китерә алмады.

## Тугызынчы бүлек

Фәргатьнең соңгы вакытта анализлары бик начарланды. Хәер, үз хәлен белү өчен аңа анализлар бирү кирәкми, ни булганын тәне үзе сөйләп тора. Гөлҗиһан никадәрле яхшы тәрбияләсә дә, Фәргать күзгә күренеп ябыга, кибә башлады. Ризыкны да ашыйсы килмичә генә ашый, авызының бернинди тәме юк, туктаусыз башы әйләнә, күңеле болгана. Ни хикмәт, сукыр күзләре сызлап җанга тия, аларга хәзер иң көчле дарулар да тәэсир итми. Авырыйм дип, эшне дә ташлап булмый, бу үзгәртеп корулар башлангач, халык түрәләр янына түгел, судларга йөри башлады. Иң көтелмәгән, элек күз алдына да китерә алмаган эшләр белән киләләр Фәргатькә. Соңгы вакытта «Маяк»ка каршы эш кузгатучылар да бар, алар — радиациядән зарар күргән Караболак, Мөслим кешеләре. Фәргать үзе дә шул сәбәпле гарип калгач, ярдәм сорап, туп-туры аның янына киләләр, «Маяк»тан суд юлы белән үзләренә матди ярдәм, ташламалар таләп итәләр. Берничә классташы белән бергә, Гөлҗиһан да «Маяк»ны судка бирде, ул да үзен атом пычрагын җыештырганда зарар күрүче буларак тануларын таләп итә. Әмма аның өчен башта Караболакның ул вакытта радиациядән зарар күрүен исбатларга кирәк. Ә ул документлар җиде кат йозак астында.

Әмма Фәргатькә башка яктан чыгучылар, басым ясаучылар да бар. Бу — шәһәр җитәкчеләре, алар артында торган «Маяк» хуҗалары, атомчылар. Алар бу эшләрнең судка барып җитүенә, судта каралуына кискен рәвештә каршы. Алар фикеренчә, берәрсенә шулай ярдәм итсәң, радиациядән зарар күргәнен танысаң, бөтен шәһәр кубачак. Тирә-юньдәге авыл кешеләре үзләренә ташламалар таләп итәчәк, Чиләбе өлкәсендә яшәүче ярты миллион авыру халыкка ярдәм итәргә кирәк булачак. Бу мөмкин хәл түгел, моның кадәр акчаны Мәскәү дә бирми, «Маяк» та күтәрә алмый. Адвокатларга гына түгел, судьяларга да әйтеп куелган: бу эшләрне кире борырга, туктатырга, уңай хәл итмәскә, халыкка үрнәк бирмәскә. Хәзергә чаклы нәкъ шулай барган да, Иртәш юристлары бу мәсьәлә белән мөрәҗәгать итүчеләрне гел кире кага барганнар. Әмма эш Фәргатькә килеп терәлгәч, проблемалар башлана. Фәргать, адвокат буларак, «Маяк»ны гаеплә-

гән берничә эшне судка хәтле китереп җиткерә алды, судьяларны, хокук яклау органнарын шушыңа өстерәп кертте, шәһәр җәмәгатьчелеген күтәрде. Бу юлы аңа мөрәҗәгать итүчеләр барысы да Иртәштә яшәүче Караболак кешеләре иде. Алар кырык елдан соң атом комбинатын үзләренә һәм халыкка күрсәткән газаплары өчен судка бирделәр.

Фәргать бу эшнең ни дәрәҗәдә авыр булачагын белә. Бәлки, аңа хакыйкатьне ачарга ирек тә бирмәсләр.

Әмма ул бу эшкә алынмыйча булдыра алмады. Чөнки аның үзенең дә, хатынының да, балаларының да, авылдашларының да бар фаҗигасе «Маяк»тан, авырулары радиациядән. Халыкка китергән бу газаплар өчен кемдер җавап бирергә тиеш иде. Җавап бирми икән, бу хәлләр тарихта теркәлеп калырга тиеш. Чөнки дөнья гел болай гына бармас, халыкны атом белән кырдыручыларга карата да хөкем сәгате җитәр әле...

Судта үзе якларга тиешле кешеләрне Фәргать бала чакларыннан белә. Бүгенге көндә алар инде илле яшьләрдә, әмма барысында да диярлек яман шеш: кайсы сукыр, кайсы аяксыз, кайсы тора алмыйча урын өстендә ята. Алар барысы да диярлек төрле группа инвалидлар, әмма бу гариплекләре радиация сәбәпле икәнлеген исбатлый алмыйлар. Шунлыктан алар барысыннан да мәхрүм — тиешле дәвалаудан да, хөкүмәт бирергә тиешле ташлама-льготалардан да, игътибардан да. Фәргатьне иң гаҗәпләндергәне шул — Мәскәү законы нигезендә тирә-күрше авыл халкы радиациядән зарар күргән булып исәпләнә һәм тиешле ярдәмен ала, ә Караболак халкы — юк. Имеш, 1957 елгы шартлаудан соң радиация болыты Караболакка кагылмаган икән, бер кырыеннан гына узган. Шундый ук зарар күргән Мөслим авылы халкы өчен Коншакта аерым йортлар сала башладылар, акчалата ярдәм иттеләр, ә Караболакка берни юк. Алар берничек тә үзләренең радиациядән зарар күрүләрен исбатлый алмыйлар. Караболак авылы хәтта картада да юк булып чыкты. Имеш, аларны 1958 елда ук башка урынга күчергәннәр. Ул заманнан калган документлар да юк, алар да, янгын чыгып, кинәт кенә янып киткән. Хәзер бу эшне бары тик шаһитлар ярдәмендә генә ерып чыгарга мөмкин. Һәм Чиләбе архивларыннан ул чорга кагылган белешмәләр эзләп карарга. Әлбәттә, бу эшне Гөлҗиһан белән бергә генә ерып чыгарга мөмкин иде, чөнки сукыр кешегә ул архивларда үзеңә кирәген тиз генә табып алу бик авыр булачак. Гөлҗиһан үзе дә бу эштә төп гаепләүчеләрнең берсе буларак бара һәм аның теләсә нинди белешмә-документларны таләп итәргә хакы бар.

Фәргать ул елларны да, Гөлҗиһанның ул чактагы хәлен дә бик яхшы хәтерли, бу исә аңа адвокат буларак нык ыша-

ныпсөйләргә мөмкинлек бирә. Фәргатьнең бүген дә хәтерендә — 1957 елның көзендә, нәкъ шул фаҗигага булган көнне, алар әтисе белән Караболакка, Гөлҗиһаннарга килгәннәр иде. Әтисенең Миасстан туган авылына күчеп кайтасы килә иде, шул хакта белешергә ул Фәргатьне ияртеп Караболакка килде. Аларны бирелән, ышанычсызлар, дип, 1947 елны сөрделәр. Чөнки Фәргатьнең әтисе немецларда әсирлектә булган, аннан илгә кайткач, аны Себер төрмәләренә җибәргәннәр. Шундый кешенең гаиләсе, әлбәттә инде, Иртәштәге атом комбинаты янәшәсендә яши алмый. Дәүләт серен ачып куюлары бар бит.

Бу Фәргатьнең, үсмер егет буларак, беренче тапкыр Караболакка килүе иде. Авылдан сөргәндә ул әле биш-алты яшьләр тирәсендә генә булган, әмма көзге салкын көндә коры арбага утырып чыгып китүен әле дә хәтерли Фәргать... Ул бигрәк тә тәрәзәгә капланып елап калган күрше кызы нәни Гөлҗиһанны яхшы хәтерли. Фәргать аны бик ярата, гел кулларында күтәреп йөри иде. Ул киткәч, аны кем карар, кем аның белән уйнар, еласа, кем юатыр дип, бик борчылган иде ул.

Инде әтисе белән Караболакка яңадан әйләнеп кайткач, каршында буй җитеп килә торган үсмер кызны күреп, ул телсез калган иде. Унбер яшьтә генә булса да, Гөлҗиһан эре гәүдәле, озын, зифа буйлы, искиткеч чибәр һәм үткен кыз бала иде. Чәчләре озын, кара, биленә төшеп тора, күзләреннән яшел нур сибелә, тыгыз бит алмалары кып-кызыл булып яна, иреннәре җиләк кебек тулы. Фәргатьнең Миасста мондый кызны күргәне юк иде. Ә үзе шундый чая, усал, яшь тай кебек, тибенеп кенә тора, янына беркемне якын җибәрми. Ә ул көлеп җибәрсә, чыңгылдаган көмеш тавыш Караболакның теге башына ишетелә.

Менә шул ут чәчәге кебек Гөлҗиһан 1957 елның көзендә, колхоз кырына эшкә киткән җирдән ярты үлеп кайтты... Ул чагында Фәргать аларда иде, бу хәлләрне бик яхшы хәтерли... Башта кичкә таба Иртәш ягында коточкыч көчле шартлау булды, аяк астында җир сикереп куйды. Фәргатьнең сугышларны күргән әтисе дә каушап калды, куркынып, бер каралып киткән күккә, бер Иртәш ягына карады. Иртәш өстендә, Уралтау тирәләрендә көмеш сыман аҗаган уйный иде. Фәргать соңыннан гына белде, бу — атом аҗаганы булган икән. Бераздан Караболак өстенә, басу-кырларга сәер соры томан таралды. Фәргать, башы әйләнеп, коса, укшый башлады, әтисе дә күкрәген тотып, җиргә чүгәләде. Аннан алар, авыз-борыннарын каплап, тизрәк өйгә йөгерделәр. Бераздан исә арбага салып, ярым үлек хәлендәге Гөлҗиһанны өйгә алып кайттылар. Иртән генә күбәләк кебек очып йөргән кыз

бала мәет кебек сузылып яткан, авыз-борыннарыннан, колакларыннан шаулап кан килә, үзе аңсыз иде... Ике йорттагы бөтен кеше Гөлҗиһанны коткарырга ташланды, югары очтан Таһирҗан бабай килеп җитте. Кем өшкерде, кем ясин чыкты, кем даруын, үләнен бирде — барысы да үлеп яткан бала тирәсендә бөтерелде. Авылда тагы күп кенә бала шушы хәлдә диделәр, өлкәннәр арасында да кинәт кенә авырып китүчеләр булды... Хәзер ул кешеләрнең күбесе юк инде... Шул чакларда көчле нурланыш алып калган Гөлҗиһан Фәргать бәхетенә исән. Әмма анда да хәзер барлык авырулар бар инде, иренә бик сиздерергә тырышмаса да, Фәргать аның газапларын җаны белән тоя, үз тәнендә кичерә. Атом тамгасы... Һәм шушыны хәзер Фәргать суд алдында исбатларга тиеш.

Тик Фәргать бу юлда үзен нинди зур каршылыклар көтеп торганын күз алдына да китерә алмый иде. Чөнки дөнья үзгәрсә дә, Иртәш үзгәрмәгән, ул һаман ябык атом зонасы булып кала бирә, дәүләт сере һаман тимерчыбыклар һәм яшерен күрсәтмәләр белән саклана. Ткаченко командасы монда әле үз көчен югалтмаган иде. Шуңа күрә «Маяк»ның да, аның артында торган атом мафиясенең дә бер сукыр татар адвокатына һәм берничә авыру авыл хатынына гына каршы торырлык көчләре бар иде. Фәргать, үзе дә белеп бетермичә, менә шушы кара көчләргә каршы көрәшкә чыкты. Аның янәшәсендә ярдәм итәргә бары тик хатыны Гөлҗиһан гына бар иде.

Фәргать бу эштә Гөлҗиһанның ярдәменә нык таянды. Чөнки Гөлҗиһан ул чорларны бик яхшы хәтерли, көнен-көнгә, сәгатен сәгатькә сөйләп бирә ала. Авылдан судка кемнәрне шаһит итеп алып килергә кирәклеген дә ачыкладылар, алар Таһирҗан бабай белән Гөлҗиһанның әнисе иде. Әмма авылдан кем генә килеп сөйләсә дә, Фәргать белән Гөлҗиһанның кулында иң кирәк нәрсә — Караболакның ул елларда радиациядән зарар күрүе турында белешмә юк иде. Һәм алар, ашыгыч рәвештә, судка хәтле Чиләбегә үзләре барып кайтырга булдылар, чөнки хат аша гына соратулары бернинди нәтиҗә дә бирмәде.

Чиләбегә килеп төшү белән, алар Таифә җиңгиләренең балаларында туктадылар. Дөрес, үз балалары янына тулай торакка да керергә булыр иде, әмма анда алар үзләре дә кеше белән яшиләр, шуңа күрә аларны борчып тормаска булдылар. Гадел белән Гадилә Чиләбедә телсез-чукраклар өчен махсус училищеда укып бетереп, шуның заводында эшлиләр, торулары да завод тулай торагында иде. Үз ишләре янында яшәгәнлектән һәм эшләгәнлектән, алар гариплекләрен бик сизмиләр кебек. Әмма Гөлҗиһанның аларга караган саен үзәкләре өзелә. Су сөлеге кебек карап торырлык балалар, ә

гариплəр арасында шулар рəтеннəн йөрилəр. Бер тапкыр əти-əни дип əйтə алмыйча, балам дигəн назлы сүзне ишетмичə, үз теллəрендə бер шигырь сөйли алмыйча, милли аһəңнəрне ишетмичə, Коръəн ишетүдəн мəхрүм булып үсте бит аның балалары. Карап торышка дүрт саннары сау кебек булса да, алар барыбер ярты кеше иде инде… Бу балалар беркайчан зур җитəкчелəр дə, зур сəясəтчелəр дə була алмаячаклар, чөнки алар телсез-чукрак, тавышсызлар иде. Бу ил, бу атом тираннары аның балаларының тавышын урлады! Җир тетрəтеп яшəгəн Алып Ханнар нəселеннəн, татар балаларыннан тавышсызлар кавеме ясады. Ничек итеп ул илне кичерəсең дə, ничек итеп бу илне яратырга мөмкин?!

Үз тормышларын корырга да ашыкмыйлар балалар. Телсез егеткə сəламəт кыз карыймы, чукрак кызны сау-таза егет аламы соң? Хəзер бөтенлəй башка заманнар бит, барысына да сау кирəк, бай кирəк. Ə балаларының бар байлыгы — тулай торакта бер карават. Кире Иртəшкə кайтып, алар янында яшəргə дə телəмилəр, чөнки Чилəбедə аларга алган белемнəре буенча эш бар, аралашырга үз ишлəре бар. Бəлки, шулар арасыннан үз парларын да табарлар əле, бəлки, бəхетлəре бөтенлəй башка җирдəдер. Теге вакытта, төшендə, Хозыр Ильяска охшаган карт: «Бу балалар сезгə җəннəт юлларын ачачак, сабыр итəргə кирəк», — дигəн иде бит. Гөлҗиһан да балаларының бəхетле буласына чын күңелдəн ышана, шуны тели, шуны көтə иде…

Əти-əнилəренең Чилəбедə икəнлеклəрен ишетеп, игезəклəр үзлəре алар янына йөгереп килеп җиттелəр. Гөлҗиһан күптəн инде алар белəн үзенчə, кул хəрəкəтлəре ясап сөйлəшергə өйрəнгəн иде, тиз генə нəрсəгə бирегə килүлəрен аңлатты. Балаларның бүген буш көннəре икəн, алар да атааналары белəн архивка барырга, кирəк булса, ярдəм итəргə алындылар. Аларның əти-əнилəре янында озаграк буласылары килə иде, шуңа күрə шəһəр архивына да бергəлəп чыгып киттелəр.

Гөлҗиһанның бу архив тирəсендə элек тə йөреп-йөреп караганы булды, əмма ул үзенə кирəк нəрсəне таба алмаган иде. Фəргать бу юлы адвокат өчен кирəкле бөтен белешмəлəр, документлар, рəсми мөрəҗəгатьлəр белəн килде. Бу юлы инде алар архивтан нəрсə кирəген белеп эзлəделəр — аларга 1959 елгы исполком карары кирəк иде. Анда Татар Караболагы авылын, радиациядəн зарар күрү сəбəпле, башка урынга күчерергə кирəклеге язылган булырга тиеш. Əгəр шушы белешмəне тапсалар, алар халыкның нидəн авыруын, кырылуын исбатлый алалар, юк икəн, аларны үлгəнче йөртəчəклəр.

Шулай итеп, алар дүртəүлəшеп архивка килеп керделəр. Аларга читтəн карап торышка ук йөрəк өзелə иде — дөм

сукыр ир, авырудан йөзе сулып саргайган ак чәчле хатын һәм аларның телсез-чукрак балалары. Алар соры таш йортлардан дөреслек эзләп йөриләр. Авырып үткән авыр тормышлары, гарип гомерләре өчен кемнәр гаепле булуына җавап эзлиләр. Ә җавап бик ерак яшерелгән, аны Иртәштән һәм Чиләбедән генә түгел, Мәскәүнең үзеннән эзләргә кирәк. Монда аерым кәгазь, белешмәләрне генә табарга мөмкин...

Әллә бу авыру ир белән хатынның кат-кат килүләрен кызганып, әллә аларның гарип балаларын күреп тетрәнеп, әллә аңлап, әллә аңламыйча, архив хезмәткәрләре алар алдына еллык карарлар теркәлгән калын-калын папкаларны чыгарып салдылар. Фәргать аларны күрми иде, биредә аның, адвокат буларак, документларны соратып алуы гына кирәк. Гөлҗиһан калтыранган куллары белән папкаларны актара башлады, аңа балалар да булышты. Аларга бары тик «Карабулак» дигән сүз генә кирәк иде... Бу папкаларны кире алып китә күрмәсеннәр дигәндәй, алар ашыгып эшкә тотындылар.

Саргая башлаган бу кәгазьләр, документлар аша Гөлҗиһан бөтенләй башка дөньяга чумды. Аның алдында тарихның кара пәрдәләре күтәрелә башлады. Монда язылганнардан кот чыгарлык иде. Җитәкчеләр ул елларда ук радиация турында бик яхшы белгәннәр икән бит! Кайда нәрсә шартлаганын да, кайда күпме радиация төшкәнен дә белгәннәр. Башларына «Үтә яшерен» дип тамга салынган менә бу карарларда өлкәдәге радиоактив пычранулар турында шактый ачык әйтелгән һәм нинди чаралар күрергә кирәклеге күрсәтелгән. Биредә кайсы авылларны кайда күчерергә, кайда нәрсә төзергә, кайсы торак пунктларны яндырырга, юк итәргә — барысы да язылган иде. Гөлҗиһанның күз алдыннан шул елларның зур, канлы фаҗигасе үтеп киткән кебек булды. Менә Чиләбе өлкә советының Теча елгасы буенда бернәрсә дә төзергә рөхсәт итми торган карары. Зур татар авылы Мөслимдә дә, елга буендагы башка авылларда да ни өйләр, ни хөкүмәт биналары төзергә ярамый, диелгән... Сәбәбе — ул тирәләрдә көчле радиация чыганагы булуы, шуңа күрә бу авылларның киләчәге булмау. Мөслим дә шул вакытта ук башка урынга күчерелергә тиеш булган, ә күчерелмәгән... Өй салырга ярамый, ә кешегә яшәргә ярый икән. Хәер, биш мең кеше яшәгән Мөслим авылы да үлеп бетеп бара бит инде, алар 1947 елдан бирле атом калдыклары ташланган елгадан су эчкәннәр. Менә ул вакытта «Маяк»та директор булып эшләгән Мишинковның бу карарга үз кулы белән язган фикере. Теча елгасы буенда яшәүчеләрне беркая да күчермәскә, чөнки аларны күчерсәң, башкалар да шуны таләп итәчәк, диелгән анда. Коточкыч хәл: җитәкчеләр үзләре үк бу авылларның радиациядән зарар күрүен таныйлар һәм... бер-

кая да күчермәскә дип карар кабул итәләр. Чөнки боларны күчерсәң, башкалар да шуны сораячак икән. Барысы да алдан ук уйлап эшләнгән, кешеләр бу радиацияле җирләрдә белә торып, үләр өчен калдырылган икән бит. Һәм аларга кырык-илле ел буе ялган сөйләгәннәр, бу авыруларда үзләрен гаепле итеп күрсәткәннәр. Һәм хөкүмәт хәзер дә үз гаебен танырга җыенмый, могҗиза белән исән калган халыкны суд юлларында йөрергә мәҗбүр итә.

Балалар да, үз чиратларында Караболак турында хәбәрләр эзләп табып, аларны тизрәк әниләренә бирәләр иде. Менә зур-зур татар авыллары — Усть-Багаряк һәм Татар Караболагы турында документлар. Алар барысы да 1957 елгы атом шартлавы һәм бу авылларга төшкән радиация белән бәйле. Аларны бу мәсьәләдә шул вакытта ук кат-кат тикшергәннәр, радиациядән зур зыян күрүләрен шул көннәрдә үк ачыклаганнар һәм бу хакта язып та калдырганнар. Җирсуны гына түгел, бу татар авылларында яшәүче кешеләрне дә тикшергән булганнар бит, аларда да зур үзгәрешләр тапканнар, нурланыш билгеләре шул вакытта ук билгеле булган. Кешеләрне генә түгел, хәтта Караболакның мал-туарларын, фуражны, терлек азыгын җентекләп тикшергәннәр, аларда да көчле радиация тапканнар, бу хакта документларга теркәп калдырганнар. Татар Караболагы авылының нинди куркыныч хәлдә булуы җитәкчеләргә башта ук билгеле булган, әмма алар халыкны коткару өчен бер чара да күрмәгәннәр.

Менә 1959 елның апрель-май айларында Караболак елгасын, урман-кырларны тикшерү турында белешмәләр. Аларда радиациянең нормадан күпкә артык икәнлеге, бу җирләрдә кеше яшәргә ярамавы теркәп калдырылган. Аларны галимнәр, шушы эш буенча махсус белгечләр әзерләгән. Акка кара белән язылган. «Бу җирләрдә алга таба яшәү кеше өчен куркыныч» диелгән. Һәм кешеләр үләргә шул җирләрдә калдырылган. Моннан соң да әле Караболак халкы кеше яшәргә ярамаган шушы үле зонада кырык елга якын җан асраган...

Шулчак Гөлҗиһан үзенә сак кына кагылганга сискәнеп китте. Кызы Гадилә икән, папкалардан ниндидер документ тапкан һәм шуны әнисенә күрсәтә. Моны күргәч, Гөлҗиһанның тәне эсселе-суыклы булып китте. Бу ул эзләгән карар иде. Караболакны күчерергә кирәклеге турында документ. Гөлҗиһан аны ашыгып кулларына алды, тиз-тиз генә күз йөгертеп чыкты. Әйе, Таһирҗан бабай белеп әйткән икән, Чиләбе башкарма комитеты Татар Караболагы авылын күчерү турында карар кабул иткән булган. Ул 1959 елның 29 сентябрендә чыгарыла, шартлау үткәч нәкъ ике елдан соң. Халыкның бер өлеше инде үлә башлагач, бер өлеше мәңгелек чир алганнан соң. Карар «О проведении дополнительных

мероприятий в зоне радиоактивного загрязнения» дип атала, һәм аның икенче пункты тулысынча Татар Караболагы авылына багышлана. Әйе, акка кара белән язылган шул — радиоактив пычрану зонасында диелгән. Бу бит Караболакның радиация астында калуын рәсми рәвештә тану дигән сүз.

— Фәргать, таптым, таптым мин эзләгән нәрсәне, — диде ул, нигәдер пышылдап кына. — Менә Караболакны күчерү турында исполком карары. Таһирҗан бабай белеп сөйләгән икән, чыннан да, булган икән андый карар.

Фәргать саргайган кәгазь битен кулларына тотып карады, анда язылган сүзләрне бармаклары белән капшады, әйтерсең лә шулай укырга, кырык елдан соң хакыйкатьне белергә тырышты. Аннан кәгазьне яңадан Гөлҗиһанга бирде, кычкырып укып чыгарга кушты. Гөлҗиһан як-ягына карап алды һәм пышылдап кына карарны укый башлады:

*«...Жителей населенного пункта Татарской Караболки Кунашакского района в количестве 2700 человек переселить на территорию восьмого отделения Тахталымского совхоза, в деревню Аширова Аливкуловского сельсовета Кунашакского района, для чего предприятию п-я 21 построить жилые дома с надворными постройками, культурно-бытовые и админстративно-хозяйственные учреждения, аналогично имеющиеся в населенном пункте Татарская Караболка... Переселение жителей из населенных пунктов Багаряк и Татарская Караболка со строительством жилых домов на станцию Тахталым и в д. Аширова закончить в 1960 году...»* диелгән. Карарга Чиләбе башкарма комитеты рәисе Г.Бездомов кул куйган, секретарь П.Карпенконың да имзасы бар.

— Бу — нәкъ без эзләгән нәрсә, — диде Фәргать дулкынланып. — Димәк, хөкүмәт шул вакытта ук таныган Караболакның радиациядән зарар күргән булуын. Таныган, белгән, әмма берни дә эшләмәгән.

Гөлҗиһан үзе дә бу хәбәрдән һаман аңына килә алмый иде әле.

Белә торып, кешеләрне үләргә калдырырга...

Картларны, яңа туган сабыйларны, җир тетрәтеп эшләп йөргән ир-атларны, авырлы аналарны череп үләргә калдырырга. Ни өчен? Ничә еллар буе фашистларны сүгәләр, ә үзләренең кай төшләре фашистлардан ким моны эшләүчеләрнең?!

— Алайса, Караболакны Тахталым белән Әширгә күчерәсе булганнар икән, — диде Фәргать, ни турындадыр уйланып. — Карар булгач, акча да бүленгән булырга тиеш күчерү өчен... Ул турыда анда әйтелмәгәнме?

— Юк, бу карарда акча мәсьәләсе кузгатылмаган, — диде Гөлҗиһан, аны кат-кат укып. — Авыл халкы ниндидер егерме биш миллион турында сөйли иде, күчерү өчен бүленгән булган, дип. Алар сөйли икән, димәк, булган инде ул. Башка кәгазьләр арасыннан эзләргә кирәктер.

— Ә монысының нотариус аша күчермәсен алырга кирәк, судка шулай гына бара, — диде Фәргать. — Мин балалар белән шушы эшне башкарып килим, син башка еллардагы карарларны да караштыр әле, акча турында булырга тиеш анда.

Фәргать архив хезмәткәрләре белән киңәшеп, карарның күчермәсен алды һәм игезәкләр белән нотариуска китте. Гөлҗиһан исә тагы бер еллык документларга кереп батты. Бу юлы ул алтмышынчы елгы карарларны карады, чөнки акча, гадәттә, ел башында бүленә иде. Бу юлы ул ашыга-ашыга бары тик Караболак дигән сүзне генә эзләп укыды. Аңа озак эзләнергә туры килмәде, бераз актаруга, ул 1960 ның 6 февралендә язылган бер белешмә тапты. Аның почмагына да «Үтә яшерен» дигән тамга сугылган иде. Белешмә башкарма комитеты рәисе урынбасары Е.Мамонтов исеменә язылган, аңа башкарма комитетның баш инженеры Э.Раск дигән кеше кул куйган. Юк, бу Караболакны күчерү өчен акча бүлү документы түгел иде, ә бу эшләрнең күпмегә төшәсе турында рәсми белешмә. Биредә дә Караболак авылында яшәүнең ни дәрәҗәдә куркыныч икәнлеге әйтелгән. Гөлҗиһан бу белешмәне күз яшьләренә тыгылып укыды, шушы кечкенә генә язмада ул Караболак халкының бөтен фаҗигасен күргән кебек булды. Белгәннәр бит, барысын да белгәннәр, Караболакны кичекмәстән башка урынга күчерергә кирәклеген таныганнар... Һәм күчермәгәннәр. Фәргать әйләнеп килгәнче, Гөлҗиһан тиз-тиз генә бу тарихи белешмәне күчереп яза башлады. Әйтерсең лә аның артында, һәр хәрәкәтен күзәтеп, Ткаченколар командасы басып тора иде. Колагында Караболакның сигез зираты шаулый, алар барысы да шушы белешмә язылганнан соң тулган каберлекләр иде.

Ул арада Фәргать тә килеп җитте, игезәкләр әти-әниләренә күчтәнәч алырга кибетләргә кереп калганнар иде. Фәргать Гөлҗиһанның тавышыннан ук аңа нидер булганын аңлады. Гөлҗиһан елаган иде. Ул иренә үзенең нинди белешмә табуын әйтте, кайбер урыннарын пышылдап кына укып та чыкты.

— Безнең авылны ул вакытта бик нык тикшергәннәр, Фәргать, — диде ул. — Бигрәк тә радиация буенча белгечләр. Һәм алар өлкә җитәкчеләрен һәр авылдагы хәл буенча кисәткәннәр. Менә тыңла әле, бу хакта ни язылган. *«По данным филиала НИИРГ от 25 июня 1959 года в районе насе-*

*ленных пунктов Багаряк и Татарская Караболка наблюдается высокая плотность загрязнения территории сел, заливной поймы и самой реки «К», а также заболеваемость среди жителей этих населенных пунктов»* диелгән. Река «К» дигәне — Караболак инде аның.

— Алар ул вакытта ук бик сак язганнар шул, — диде Фәргать, бу урынны тагы бер тапкыр укытып. — Сизәсеңме, монысында инде радиация дигән сүз юк. Аннан соң нәрсә диелгән әле?

— *«Комиссия филиала НИИРГ считает, что дальнейшее проживание населения в селах Багаряк и Татарская Караболка опасно и рекомендует немедленное их отселение»* диелгән. Караболакта ул вакытта 604 хуҗалык булуы һәм анда 2638 кеше яшәве әйтелгән. Аларны башка урынга күчерү 78,5 миллион сумга төшәсе исәпләп чыгарылган. Караболакта ул вакытта халык күбрәк яши иде, әлбәттә, монда нигәдер киметеп күрсәтелгән. Хәер, алтмышынчы еллар башында шактый кеше үлгән иде шул инде.

— Бу белешмәдән күренгәнчә, СССР Министрлар Советы 1957 елның 12 ноябренә үк инде махсус карар кабул иткән булган икән. Ягъни шартлау булу белән. Министрлыклар, Мәскәү галимнәре бер ел эчендә халыкның бу җирләрдә яши алу-алмау мәсьәләсен өйрәнергә тиеш булганнар. Әмма алар дәшмәгәннәр булып чыга инде. Яки аларга бу хакта дәшмәскә кушканнардыр. Җирле белгечләр Караболак белән Багарякны кичекмәстән күчерергә тәкъдим иткәннәр, ә Мәскәү дәшмәгән. Шулай итеп бөтенесе үз урынында утырып калган. Ә бит Караболакны күчерү өчен суммасы да күрсәтелгән булган — ул заман акчасы белән җитмеш сигез миллион ярым. Бу акча бүленгәнме, юкмы, бүленсә, кая киткән — билгеле түгел. Безгә суд өчен болары да бик җитеп торыр. Игътибар иттеңме, күчәсе кешеләргә йортларны «Маяк» төзисе булган бит, 21 нче почта ящигы, дигән. Менә шуннан курыккан инде алар, үләсе кешеләр өчен артык акча туздырудан.

— Син кара әле, Фәргать, — дип, аны дәвам итте Гөлҗиһан. — СССР хөкүмәте шартлау булуга нинди кабахәт карар чыгарган! Имеш, ел дәвамында халыкны өйрәнергә — яши аламы ул радиацияле җирләрдә, әллә юкмы? Коточкыч бит бу! Бер ел буе кешеләрне атом калдыклары арасында махсус тоту! Үлеп бетсәләр — үлеп беткән булалар, алар өчен проблемалары калмый, үлеп бетмәсәләр, димәк, радиацияле зонада да яшәп була икән. Менә шуңа күрә дә калдырганнар инде алар безне. Үлеп бетмәгәнгә күрә. Өйрәнергә кирәк булганга күрә. Бу, әлбәттә, «Маяк» белән бергә эшләнгән этлек, шуңа күрә «Маяк» бүген бер кәгазь бирмәс

өчен җан тартыша. Менә шуларның барысын да судта күтәрербез, Алла боерса.

Гөлҗиһан архив документлары арасында Караболакка кагылган тагы берничә бик мөһим белешмә тапты. Үзләренә кирәкле документларны тиешле рәвештә күчермәләрен алгач, алар архивтан чыгып киттеләр. Шушы берничә бит кәгазьгә бөтен Караболакның фаҗигасе, Гөлҗиһан еллар буе эзләгән сорауларга җавап сыеп беткән иде. Алда аларны Иртәштә «Маяк» атом берләшмәсе белән суд көтә иде…

## Унынчы бүлек

Ниһаять, суд буласы көн билгеләнде.

Инде Караболактан шаһитларны — Таһирҗан карт белән Гөлҗиһанның әнисен алып килергә кирәк иде. Әмма ябык зонага читтән кеше кертү — үзе бер бәла, аның мәшәкате шактый. Шәһәргә керергә тиешле кешеләр исеменнән махсус органнарга алдан гариза язасы, аны Мәскәүгә җибәреп, ФСБдан айлар буе җавап көтәсе. Әгәр син хөкем ителгән булсаң яки милициядә хисапта торсаң, органнар өчен шикле кеше булсаң, шәһәргә керергә рөхсәт бирмиләр. Караболактан килүче карт-карчык андый кешеләр булмаса да, судьядан да язу кирәк, ул аларның судка керүләрен алдан органнарга хәбәр итеп куярга тиеш. Керү-чыгуның көне-сәгате бик төгәл куелырга һәм үтәлергә тиеш, бигрәк тә — шәһәрдән чыгу. Әгәр син күрсәтелгән вакытта шәһәрдән чыкмыйсың икән, сине, эзләп табып, утыртып куярга мөмкиннәр. Шуңа күрә Гөлҗиһан судка авылдан шаһитлар китерүгә бик җентекләп әзерләнде, бу планның бер генә җирендә дә өзеклек чыгарга тиеш түгел иде, алардан башка суд булмаячак кына. Ә бу карт-карчыкның юлларын өзәр өчен тиешле органнар барысын да эшләргә мөмкин, чөнки бу суд «Маяк»ка кирәк түгел. Дәүләт сере Иртәштә әле дә менә шулай каты саклана, атом адәмгә караганда кирәгрәк иде.

Гөлҗиһан кичтән Караболакка кайтып кунды һәм иртәниртүк, әнисе белән Таһирҗан картны, алдан сөйләшенгән машинага утыртып, Иртәшкә алып китте. Билгеләнгән сәгатьтә алар инде шәһәр капкасы янында басып торалар иде. Машинаны кире Караболакка җибәрделәр, чөнки аны барыбер монда кертмиләр. Гөлҗиһан үзенең беренче тапкыр шушы таш койма янына килеп баскан вакытларын исенә төшерде. Адым саен мылтыклы сакчылар, өскә ябырылырга торган этләрне күреп, Гөлҗиһан куркып калган иде. Үзен бер бүлмәгә алып кереп, чишендереп тентегәннән соң, ул бик хурланды, әгәр Фәргатьне эзләп табасы булмаса, ул биредән кер-

мичә кире борылып киткән булыр иде. Аяк атлап керде һәм бөтенләйгә шушы атом шәһәрендә калды.

Гөлҗиһан сиксән яшьлек әнисенә, йөз яшьлек Таһирҗан бабасына карады. Алар да бу атом шәһәренә беренче керәләр иде.

Гөлҗиһан әнисен элегрәк тә кыш чыгарга бирегә чакырып карады, артыннан йөреп, ул аны үз янына кертә ала иде. Әмма карчык теләмәде, Иртәш ягына борылып та карамады. Әйтерсең лә анда аждаһа үзе яши, әйтерсең лә Иртәштән бөтен дөньяга явызлык тарала. Хәзер дә ул кызы хакына гына ризалык бирде, әмма суд бетүгә, кайтып китәсен әйтте. Чөнки өйдә Баһадур берьялгызы калган иде, карчык бу җәһәннәм базыннан тизрәк оныгы янына кайтып китәргә ашыкты. Таһирҗан карт та шундый ук шарт белән керде, суд бетүгә, бүген үк Караболакка кайтып китәргә. Алар икесе дә сагаеп, өркешеп калганнар, ничә еллар буе Караболак халкын йотып яткан бу шәһәргә теләр-теләмәс кенә кереп киләләр.

Башта карт-карчыкны бик җентекләп компьютерда тикшерделәр. Исем-фамилияләре дөрес язылганмы, документлар дөрес тутырылганмы, алар каршында чыннан да шушы кешеләр басып торамы, хөкем ителмәгәннәрме, милициядә хисапта тормыйлармы? Аннан аерым бүлмәләргә алып кереп китеп, чишендереп, капшап карадылар, моның белән диндәге карт-карчыкның бөтенләй котларын алдылар. Ул бүлмәләрдән чыкканда, алар күтәрелеп карарга да оялалар, рәнҗетелгән балалар кебек, елап җибәрергә әзер иделәр. Мөселман-татарларга чит кеше каршында чишенүнең гөнаһ икәнлеген Гөлҗиһан әйтеп караса да, Иртәш проходноеның үз тәртибе, үз законнары бар иде... Алар йөз яшьлек татар картыннан да шпион эзләделәр һәм чак кына тапмыйча калдылар. Таһирҗан карт паспортындагы фотосына бөтенләй охшамаган, анда ул җыерчыклы бабай, ә монда шоп-шома битле үсмер малай кебек иде. Моңа тикшерүчеләр дә игътибар итте, бер аның паспорттагы фотосына, туган елына карадылар, бер чекрәеп картның үзенә текәлделәр. Аннан аптырап: «Сиңа ничә яшь, бабай?» — дип сорап куйдылар. «Йөз тулды...» — диде карт, берни булмагандай. «Ә фотоңдагы җыерчыкларың кая китте?» — дип, тагы да гаҗәпләнеп сорады шәһәр сакчылары. «Анысын сез саклаган атом белә инде», — диде карт, берни булмагандай. Аларга Аллакүл чишмәсе, зәңгәр балчык, көнгә биш тапкыр укыган намазлар турында сөйләп тормассың бит инде. Галимнәр, әлбәттә, аның турында, радиациянең кире тәэсире, мутация, диләр. Монысын бер Аллаһ кына белә инде.

Аларны шулай җентекләп тикшергәннән соң, бүген үк кире чыгасыларын кисәтеп, шәһәргә кертеп җибәрделәр. Гөлҗи-

һан шунда ук капка төбендә басып торган таксины алды, һәм алар бик тиз өйгә кайтып җиттеләр. Судка хәтле карт-карчыкны бераз ял иттереп, чәйләр эчеп, намазлар укып, тагы кузгалдылар. Фәргать инде судка иртән үк киткән иде, аның дәгъва бирүчеләр белән очрашасы, кайбер нәрсәләрне алдан сөйләшеп куясы бар иде.

Судка Иртәштә яшәүче бөтен Караболак халкы килгән булып чыкты. Алар Таһирҗан карт белән Хәбирә карчыкны кочаклап ук алдылар, инде күптән гүр иясе булган үз әти-әниләрен күргән кебек булдылар. «Маяк» ягы да судка күп булып, яуга кергән кебек нык әзерләнеп килгән иде. Хөкүмәт кешеләре, социаль яклау бүлегеннән килгән вәкилләр дә атомчылар ягында булып чыктылар. Шулчак залга кара күзлек кигән бер сукыр картны кертеп утырттылар. Гөлҗиһан аны шунда ук таныды, бу — КГБ генералы Ткаченко иде. Ул да «Маяк» атом комбинатын якларга килгән булып чыкты. Шулай итеп, зал башта ук икегә аерылды — атомчыларны, хөкүмәтне гаепләп дәгъва белдергән Караболак халкы һәм бөтен көчләренә «Маяк»ны якларга алынган атом түрәләре, хөкүмәт вәкилләре.

Судта беренче сүзне Гөлҗиһанга бирделәр:

— Мин 1946 елның 2 сентябрендә Коншак районының Татар Караболагы авылында туганмын, — дип башлап китте ул үзенең сүзен, тыныч булырга тырышып. — Нәкъ шул вакытта биредә, Иртәштә, беренче атом реакторы өчен чокыр казый башлаган булганнар. Минем тормышыма һәм атом бомбасына бер чорда нигез салынган. Миңа ике яшь вакытта Иртәштә беренче атом реакторы эшли башлый, өч яшемдә вакытта биредә беренче атом бомбасы ясала. Мин атом промышленносте белән бәйле бөтен пычракны, радиацияне, атом калдыкларын тәнемә, каныма сеңдереп үскәнмен, чөнки безнең авыл биредән кырык кына чакрым. Ә атом объектлары булган җирдә йөз чакрым радиуста тирә-юньдә кешеләр яшәргә тиеш түгел. Безгә билгеле мәгълүматлар буенча, «Маяк»та инде 1948 елны ук беренче атом реакторын эшләтеп җибәргәндә зур авария була, ул сменада эшләүче бөтен хезмәткәрләр үлем нурланышы алалар. «Маяк» комбинатында галимнәр теркәп барган гына да иллеләп атом авариясе, шартлаулар, радиация таралу фактлары була, мин боларның барысын да, Чиләбе экологларыннан алып, судка тапшырдым. Ә һәр авария ул — тирә-якка үтергеч радиация таралу, елгаларның, туфракның, һаваның радиоактив матдәләр, атом калдыклары белән агулануы дигән сүз. Алар аша болар барысы да кешегә күчә. 1952 елга кадәр «Маяк»ның бөтен атом калдыкларын турыдан-туры Теча елгасына ташлап барганнарын истә тотсак, ни өчен бу тирәдә халыкның рактан

кырылуын аңларга була. Ул вакытта гына да елгага өч миллион кюри атом калдыгы ташлана. Шулай итеп без, атом комбинаты янында яшәүче Татар Караболагы авылы халкы, «Маяк» эшли башлаган беренче көннәрдән үк көчле радиация астында яшәргә мәҗбүр ителгәнбез, әмма моны безгә беркем дә әйтмәде.

Инде хәзер билгеле булганча, 1957 елның 29 сентябрендә «Маяк»та көчле шартлау була. Моны атом калдыклары саклый торган резервуар шартлаган дип баралар, ә галимнәрнең әйтүе буенча, ул вакытта биредә атом бомбасы шартлаган булырга тиеш. Аларның әйтүе буенча, бу шартлау Чернобыльнекенә караганда күпкә көчле була, тирә-юньгә егерме миллион кюри атом калдыклары тарала, ике йөз меңнән артык кеше нурланыш ала, шулар арасында без, Караболак халкы да булабыз.

«Маяк» вәкилләренең залда журналистлар утырганда бу хәтле тирәнгә керәселәре килми иде, күрәсең, алар адвокатлары белән киңәшеп алдылар. Моны күреп, судья шунда ук Гөлҗиһанны туктатырга ашыкты:

— Мәсьәләгә якынрак килегез, үзегез турында гына сөйләгез, — диде ул аңа, шактый кырыс тавыш белән.

— Монда барысы да бергә бәйләнгән һәм «Маяк» турында сөйләмичә булмый иде. Чөнки безнең бөтен бәлабез шуннан булды.

— Бу исбат ителгән нәрсә түгел, мәсьәләгә якынрак килегез, — дип, тагы аны бүлдерде судья.

— 1957 елның 29 сентябрь көнендә без колхоз кырында бәрәңге ала идек, — дип дәвам итте Гөлҗиһан, күңеле белән шул чорларга китеп. — Көн инде кичке якка авышып бара иде. Кинәт кенә көчле шартлау булды һәм җир сикереп куйды. Башта күк йөзе караңгыланды, аннан кырга әллә нинди сәер томан таралды. Балалар коса, укшый башладылар, чөнки тирә-якта сасы, бозылган йомырка исе килә иде. Мин дә коса башладым, бик нык башым авырта башлады, кисеп-кисеп эчем авыртты, бөтен җиремне көзән җыерды. Мине өйгә ат белән алып кайтканнар. Ул вакытта миңа унбер яшь иде. Өйдә берничә көн шулай авырып ятканнан соң, безне тагы кырга чыгардылар. Бөтен алган бәрәңгебезне кире чокырларга күмдерделәр, аны ашарга ярамый, диделәр. Ни өчен ярамаганын әйтмәделәр. Без барыбер кырда шул бәрәңгене пешереп ашадык, Караболактан су эчтек, чөнки кырда башка нәрсә юк иде. Ноябрь аена хәтле, беренче кар төшкәнче, без кырда яшелчә-бәрәңгене тирән траншеяларга күмеп йөрдек. Алар барысы да радиацияле булган икән. Кыш көне исә, әниләр белән бергә, миннек, җон яндыруда эшләдек, кырда салам яндырдык. Аларның барысына да радиация тузаны

утырган булган, шуңа карап торып юк иттергәннәр. Анда да гел костык, кайберәүләр, аңнарын югалтып, кар өстенә авалар иде.

1958 елның язында исә, җир кардан ачылу белән, безне, мәктәп балаларын, бөтен авыл халкын күршедәге Урыс Караболагы авылына эшкә җибәрделәр. Аларны инде башка урынга күчергәннәр иде, без шуларның радиацияле пычрак җирләрен җыештырырга тиеш идек. Эшкә чыкмаган кешеләрнең утырткан бәрәңге бакчаларын сукалап ташладылар, малларын көтүгә чыгармый башладылар. Бөтен Татар Караболагы халкын мәҗбүри рәвештә радиацияле урынга эшкә кудылар. Хәтта авырлы хатыннарны да, хәтта беренче класс балаларын да. Безне милиция, солдатлар белән мылтык астында алып баралар иде эшкә, кире дә шулай сак астында кайта идек. Шулай итеп без Урыс Караболагы авылында таш чиркәүне, мәктәп, кибет кебек кирпечтән салынган биналарны сүтүдә, чистартуда катнаштык. Балаларның, хатын-кызларның эше кирпечләрне аралау, кырып чистарту, күрсәткән җиргә ташу иде. Без аларны күкрәкләребезгә куеп ташыдык, ә алар барысы да радиацияле булган. Без яланкул, яланаяк эшләдек, кулларыбыз сыдырылып, канап бетә иде. Без инде шул вакытта ук көчле радиация алган булганбыз. Ул арада авылда берничә бала үлеп китте, олылар кинәт кенә авырый башлады, әмма моның сәбәбе белән беркем кызыксынмады.

Шул елның май аенда безне, мәктәп балаларын, Урыс Караболагы авылы урынына яшь карагай үсентеләре утыртырга җибәрделәр. Без Чиләбе — Свердловск трассасы буйлап агачлар утырттык. Соңыннан билгеле булганча, ул җирләрдә радиация бер квадрат метрга мең кюри булган, ягъни без сәгатенә мең микрорентген радиация фоны булган урында эшләгәнбез. Безне мылтыклы солдатлар, милиция карап торып эшләтте. Безгә беркем дә монда ашарга-эчәргә ярамаганын әйтмәде. Шул елның июль аенда мин бик каты авырып киттем, температурам ай буе кырык градус булган, чәчләрем коелды. Шул вакытта мин бик каты нурланыш алганмын... Чиләбе медучилищесында укыганда, мин кан анализларымның бик начар икәнлеген белдем. Хәзер миндә өченче дәрәҗәле яман шеш, диабет, бавырым бик зурайган, йөрәгем белән хисапта торам. Канымда атом тамгасы — генетик үзгәреш йөртәм. Кияүгә чыккач, озак еллар бала тапмадым. Аннан беренче игезәк балаларым тумыштан телсез-чукрак булып тудылар. Аннан берничә үле бала таптым. Соңгы улымның кан анализлары яхшы түгел, анда да диабет башланды. Ирем дә Иртәштә солдат хезмәтендә вакытта көчле радиация алып, дөм сукыр калган кеше, ул бүген биредә адвокат

буларак катнаша. Минем белән бер класста укыган егерме тугыз баланың инде егермедән артыгы рактан үлде, бөтен укытучыларым үлеп бетте. Әти җитмешкә дә җитмичә рактан үлде, ике аягын кисеп тә коткара алмадык. Югыйсә безнең нәселне авылда Алыплар дип йөртәләр, һәм алар туксан-йөзгә хәтле яшәгәннәр. Биредә әни утыра, анда да яман шеш. Ике ир туганым онкология буенча хисапта торалар. Мин боларның барысын да радиация тәэсиреннән дип хисаплыйм һәм хөкүмәттән, безне, белә торып, шундый җирләрдә яшәткәне өчен, бездән радиация пычрагын җыйдырган өчен, безне гарип калдырган өчен, тиешле компенсация таләп итәм. Үземне ликвидатор итеп тануларын сорыйм. Әлбәттә, бу тану һәм ташламалар миңа һәм минем авылдашларыма югалган сәламәтлегебезне кире кайтармый, әмма бу хакыйкатьне торгызу булыр иде. «Маяк» минем балачагымны, яшьлегемне урлады, бөтен гомеремне авырып уздырырга мәҗбүр итте. Дәүләт минем һәм минем авылдашларым өстендә атом тәҗрибәсен уздырды. Алар соң булса да үз гаепләрен аңларга һәм үлеп бетмәгән халыкка ярдәм итәргә тиешләр. Минем соравымны кире какмавыгызны сорыйм...

Гөлҗиһан сөйләгәндә, залда шылт иткән тавыш булмады.

«Маяк» һәм хөкүмәтнекеләр кара янып, Караболак халкы күз яшьләре белән Гөлҗиһанны тыңладылар. Журналистлар исә ашыга-ашыга нидер яздылар, мондый судны алар әле беренче тапкыр күрәләр, «Маяк» хәтле «Маяк»ны гаепләү сүзләрен беренче тапкыр ишетәләр иде. Судья да аңлап алды — аның каршында надан бер авыл хатыны түгел, мәсьәләне бөтен яктан да белгән, аңлаган һәм үз хокукларын бик көчле дәлилләр белән исбатлый белгән кеше басып тора иде. Ә судьяга кире карар чыгарырга, бу эшне туктатырга кирәк, чөнки бөтен өлкә буенча шундый әмер бирелгән. Шуңа күрә ул Гөлҗиһанга өстәмә сораулар биреп тормаска булды, чөнки аның дәлилләрен кире кагу мөмкин түгел иде.

Аннан соң сүз шаһитларга бирелде. Беренче булып Таһирҗан бабай сөйли башлады:

— Биредә утыручы Караболак кешеләре — барысы да хөкүмәтнең ялгыш сәясәт алып бару нәтиҗәсе, атом корбаннары алар, — дип, иң кирәк сүзләрдән башлап китте ул. — Халыкка ул вакытта ук дөресен әйткән булсалар, корбаннар да бу хәтле күп булмас иде. «Маяк» эшли башлаганнан бирле, Караболакта кинәт үлем белән яки бик нык газапланып ике меңгә якын кеше үлде, сигез зират тулды. Мин шул авылның мулласы, мәетләрнең исемлеген үзем алып барам, үзем җеназа укып күмәм, алар барысы да минем кул аша үтте. Хәзер Гөлҗиһан кызым Чиләбе больницасы аша тикшереп

белде, бу мәрхүмнәр барысы да рактан китеп барган булганнар икән. Бу хакта аларга беркем берни әйтмәде. Әйе... Караболакта мондый хәлнең гомердә дә булганы юк иде, безнең авыл бөтен тирә-якка халыкның озак яшәве белән данлыклы иде, бездә йөз илле яшькә җиткән кешеләр дә була иде. Әйе... Ә хәзер тууга үләләр яки туганчы ук. Бөтен авылны гарипләр, диваналар басты. Болар барысы да радиация нәтиҗәсе булган икән, без моны перестройка җиткәч кенә аңладык, Чернобыль шартлагач кына. Әйе... Ә безнең гел үзебезне гаепләделәр, имеш, дөрес ашамыйбыз, дөрес яшәмибез...

— Бабай, темага якынрак кил әле, — дип, судья аны бүлдерергә мәҗбүр булды.

— Темасы шул инде — бу балаларны хөкүмәт үзенең җинаятен каплауда файдаланды, — дип дәвам итте Таһирҗан карт. — Мин ул вакытта колхозда эшли идем, яшьләргә машина-тракторда ярдәм итә идем. Илле җиденче елны Иртәштә атом шартлаганда, без барыбыз да кырда идек. Бу балалар колхоз бәрәңгесен ала иде. Шартлау артыннан ук бөтен дөнья караңгыланып китте, сасы ис таралды. Балалар эчләрен тотып бөгелеп төштеләр, күпләр коса башлады. Гөлҗиһанның борыныннан кан китте, аңын җуйды. Аны, атасының атына салып, авылга алып кайттык. Авылда ул вакытта табиб юк, ул хәзер дә юк әле, үзебез ничек беләбез, шулай алып калдык баланы. Терелеп җитмәс борын, аларны тагы кырга кудылар, алган бәрәңгеләрен җиргә күмдерделәр. Гөлҗиһан кызым да кара көзгә хәтле шунда эшләде, радиация тузанын йотты. Ә икенче елны яз җитү белән, бөтен авыл халкын Урыс Караболагына кудылар. Мин үзем дә анда булдым һәм бу балаларның, Гөлҗиһан кызымның сәламәтлек өчен зарарлы булган урыннарда эшләвен үз күзләрем белән күрдем. Безне, концлагерьдагы кебек, автоматлар белән саклап эшләттеләр. Чиркәүне ломнар белән генә җимерә алмагач, хәрбиләр килеп шартлатты. Аннан менә бу балалар атна буе аның кирпечләрен араладылар. Ә алар барысы да радиацияле булган бит, ул хакта безгә берни әйтмәделәр. Әле җитмәсә, яхшырак кирпечләрне үзебезнең авылга алып кайтырга куштылар, аннан дуңгыз фермасы төзеттеләр. Әмма ул радиацияле бинада дуңгыз малы да чыдамады, үлеп, кырылып бетте. Әйе... Аннан мәктәп балаларын агач утыртырга җибәрделәр, һаман шул пычрак, радиацияле җирләргә инде. Җәй буе шунда чиләнделәр, мескеннәрем. Мин үзем дә анда идем, машина белән үсентеләр ташып тордым. Шунда Гөлҗиһан бик нык авырып китте, бу юлысында инде үлә икән дип, бик курыктык. Ай буе, берни белми, кан косып ятты. Алдан, арттан, колакларыннан — бөтен җиреннән кан китте. Башында чәчләре коелып бетте баланың. Ул көннәр-

дә мин үзем аның янында булдым, шуңа күрә хәлен бик яхшы беләм. Авылда берничә бала шулай үлеп тә китте. Аллаһ ярдәме белән, без Гөлҗиһанны аякка бастырдык, әмма аның тәнендә, канында мәңгегә бу авырулар калды. Алары турында үзе сөйләде инде, кабатлап тормыйм. Мин Аллаһы Тәгалә алдында шаһәдәтлек бирәм — Гөлҗиһан кызым да, минә бу хатыннар да — барысы да шул елларда гомерлек чир алган кешеләр. Хөкүмәт алар алдында бик гаепле, соң булса да, үз ялгышын төзәтсен, ярдәм итсен аларга. Сезнең дә Аллаһ каршында җавап бирәсегез бар, шуңа күрә гадел хөкем чыгарыгыз, бу авыру хатыннарны тилмертеп йөртмәгез...

Судьяның хәлне бераз җиңеләйтеп аласы килде, ахры, ул сүзен шаяруга борды:

— Бабай, менә белешмәңә карап утырам, сиңа йөз яшь икән бит инде! Авылда шундый көчле радиация булгач, ничек соң сиңа тимәгән ул? Сиксәнгә, йөзгә җитәрлек кешеләре булгач, димәк, ул авылда хәлләр алай ук куркыныч түгел?

— Мин Аллаһ кушканча яшәргә тырышам, намазларымны калдырмыйм, — диде Таһирҗан карт, бик җитди итеп. — Совет власте халыктан динне алды, авылга аракы кертеп тутырды. Имеш, аракы яман авыруларны бетерә. Сыер савучыларга, механизаторларга хезмәт хакы урынына очсызлы аракы бирә башладылар. Халыкны боздылар. Элек бер мин генә түгел, күпләр йөзгә җитә иде. Хәзер исә бер яктан — радиация, икенче яктан — урыс аракысы халыкны кырып салды. Боларның барысына да хөкүмәт гаепле...

Судья инде бу соравын ник биргәненә үкенеп куйды, чөнки татар карты тагы әллә кайларга кереп китте. Бу авыл халкы сүзгә, фикергә кесәгә керә торган түгел иде, һәм ул алар белән саграк булырга кирәклеген аңлады. Шуңа күрә сүзне тизрәк икенче шаһитка — Гөлҗиһанның әнисенә бирде. Әмма гомерендә дә авылдан чыкмаган татар карчыгы урысча белми иде, аңа тәрҗемәче эзли башладылар. Әмма атом шәһәрендә, урыс судында ничек инде татарчадан профессиональ тәрҗемәче табарга мөмкин? Меңләгән татар яшәгән һәм эшләгән шәһәрдә атом бомбасы ясау мөһимрәк бит, татар белгечләре әзерләү түгел. Һәм әнисенең сөйләгәннәрен Гөлҗиһан үзе тәрҗемә итәргә булды.

Хәбирә карчыкның хәтере ул хәтле үк яхшы булмаса да, ул кызының илле җиде-илле сигезенче елларда бик нык авыруын, кан косып ятуын елый-елый сөйләде.

— Инде үлә икән дип уйлап, кырык ясин чыгып, кәфенлекләр дә әзерләп куйган идек инде, — дип, татарчалап сөйләвен дәвам итте ул. — Гел саташып, ут эчендә ятты бит. Башта бәрәңге кырыннан шундый булып кайтты ул, анысы җиңелрәк үткән иде. Кырда мин үзем дә аның янында идем,

авырый башлауга шундук төреп алып, алып кайтып киткән идем. Урыс Караболагы авылында да кызым белән бергә эшләдек, аңа авыр булмасын дип, агулы кирпечләрне үзем күбрәк күтәреп ташый идем. Бер көн калдырмый икәүләп Урыс Караболагына чиркәү сүтәргә эшкә чыктык. Шуннан соң дегеткә чорналган үле бала таптым. Гөлҗиһан исә җәй буе шунда агач утыртып йөрде, июль аенда кинәт кенә каты авырый башлады. Кырык көн сакладык балакаемны. Алланың рәхмәте белән исән калды инде. Бөтен нәселгә бер таяныч булды бу бала, әмма үзе дә гомер буе сәламәтлеккә туймады. Ул болар хакында безгә сөйләмәде, бөтен газапларын эчендә тотты. Бөтен авылга ярдәм итте. Рәхмәт, балам, халык синнән риза, Аллаһ та риза булсын…

Карчык шул сүзләрне әйтте дә елап җибәрде. Гөлҗиһан әнисенең соңгы сүзләрен тәрҗемә итеп тормады, бу урыс-марҗа өчен аның әһәмияте юк иде. Ул әнисен тынычландырып, тизрәк урынына утыртты, термос белән алып килгән чәен салып эчерде, даруын бирде. Үзе дә тиз генә учы белән төрле-төрле даруларын эчеп куйды, чөнки аның йөрәге инде бөтенләй оеп беткән, теле чак әйләнә иде. Кеше каршында авып китмәс өчен, ул тизрәк әнисе янына килеп утырды.

Судның иң кискен, иң хәлиткеч мизгеле җиткән иде. Сүз Гөлҗиһанның адвокатына — Фәргатькә бирелде.

«Маяк»ныкылар да, судья да, хәлиткеч көрәшкә әзерләнгән кебек, тынып, сагаеп калдылар. Чөнки иң көтелмәгән дәлилләрне ул китерергә мөмкин иде. Һәрхәлдә, судья өчен инде барысы да хәл ителгән булса да, ул да Фәргатьне зур игътибар белән тыңлый башлады. Сорауларны да шуңа бирергә килешкәннәр иде…

Фәргать тә судка бик нык әзерләнеп килгән иде.

Бу вакыйгаларның тере шаһитларыннан тыш, аның кулында хәзер Чиләбе архивыннан алган белешмә бар. Хәзер башка заман, хәбәрдарлык чоры, һәм Фәргать халык хөкеменә Иртәш хакында, «Маяк» турында бар дөреслекне чыгарырга тиеш иде.

— Әгәр 1957 елда «Маяк»та булган атом шартлавын яшермәсәләр, бәлки, Чернобыль фаҗигасе дә булмас иде, — дип, ул үзенең сүзен зур сәясәттән башлап китте. — Ә биредәге хәлләр Чернобыльгә караганда да куркынычрак, шартлау андагыдан да көчлерәк булган бит, бу турыда хәзер галимнәр әйтә. Чернобыльдән исә бер Украина һәм Белоруссия генә түгел, Россиянең унтугыз өлкәсе һәм республикасы зыян күрде, атом болыты Англия, Франция, Скандинавия илләренә хәтле барып җитте. Чернобыль шартлавы өч йөз атом бомбасы көченә тиң, дип яза галимнәр, ә «Маяк»тагы шартлау нәрсәгә тиң? «Маяк»ның зыяны тирә-якка меңнәрчә чак-

рымнарга хәтле таралды, төньяктан Кар диңгезенә хәтле барып җитте. Ничек инде ул радиация болыты биредән утыз-кырык чакрым чакрым җирдәге Татар Караболагы авылына керми үтеп китсен икән? Чернобыль нәтиҗәсендә миллионга якын кеше нурланыш алган, Чиләбе өлкәсендә хәзергә ярты миллион шундый авыру яшәгәнлеге билгеле. Татар Караболагы авылы халкы да шулар арасында, әмма хөкүмәт моны һаман танырга теләми, аларга ярдәм итми. Моңа хәтле «маяк»чыларның да, хөкүмәтнең дә бу мәсьәләдә фикере бер булды, имеш, Караболак авылы радиациядән зарар күрмәгән, шуңа күрә ярдәм алырга хакы юк. Безне еллар буе шулай дип ишектән-ишеккә, архивтан-архивка куып йөрттеләр, безнең мондый белешмә таба алмаячагыбызга хөкүмәт нык ышанган иде. Чөнки җеп очын яшерүчеләр дә алар үзләре иде. Әмма ялганны күпме генә яшерсәң дә, аның бер очы чыга, безнең татарда шулай диләр. Таптык без Татар Караболагы авылының радиациядән зарар күрүе турында белешмәне, менә ул... Авыл инде 1959 елда ук башка урынга күчерелергә тиеш булган, әмма күчерелмәгән, моңа да хөкүмәт һәм атомчылар гаепле, без анысына да документлар таптык. 1959 елгы исполком карары белән Татар Караболагы авылы радиациядән зарар күргән дип исәпләнә икән, ничек аның халкы зарар күрмәсен ди?! Ничек менә бу сезнең каршыда утырган хатын-кызлар зарар күрмәсен? Мин сукыр кеше, бу документларны сезгә кычкырып укып бирә алмыйм, әмма мин аларны яттан беләм, яттан өйрәндем...

Фәргать шулай диде дә Чиләбе архивыннан алып кайткан белешмәләрне сүзен-сүзгә яттан сөйләп бирде. Аннан бу документларны йөзе таш булып каткан судья ир каршына китереп салды. «Маяк»чылар мондый кискен борылыш көтмәгәннәр иде, алар тиз генә үзләренең адвокатлары белән киңәшеп алдылар. Түрдә утыручылар югалып калдылар, чөнки бөтен өлкә буенча беркемгә дә радиация белән бәйле архив белешмәләрен күрсәтмәскә, бирмәскә дип әйтеп куелган иде. Ә бу сукыр адвокат кулында нәкъ шул документлар. Анда акка кара белән Татар Караболагы авылының радиациядән зарар күрүе турында язылган һәм башка урынга күчерелергә тиешлеге әйтелгән.

Әмма судья ир үзен бик тиз кулга алды.

— Сез темага якынрак килегез әле, — диде ул, үзенең яраткан алымын кулланып. — Чернобыль турында без дә бик яхшы беләбез, «Маяк»тагы шартлаудан соң да хөкүмәт күп эшләде. Күпме авыллар башка урынга күчерелде. Эш анда түгел. Сез яклый торган дәгъвачылар үзләрен радиация пычрагын җыештыруда катнаштык дип баралар. Әмма аларның бу хакта бер генә белешмәләре, документлары да

юк бит! Аларга анда барырга кем әмер биргән, приказ дәфтәрләре сакланганмы, булса, нигә алар безнең кулда юк? Йөзгә җиткән карт-карчык сүзе белән генә хөкем карары чыгарып булмый бит. Документлар кирәк, документлар. Бармы алар сездә — менә шуны әйтегез сез...

Фәргать бу сорауны көткән иде. Чөнки моңа кадәр Коншакта, Чиләбедә булган судларда да халыктан гел әнә шундый белешмәләр сорап теңкәләренә тигәннәр. Ә авыл халкында андый белешмә каян булсын? Һәм барысын да кире борганнар. Хәзер судья аны да шул почмакка куып кертмәкче була. Башта, Караболак радиациядән зарар күрмәгән, дип, еллар буе тукып килделәр, инде андый документны тапкач, яңа белешмә сорый башладылар...

— Аларның андый белешмәләре юк, сез бик яхшы беләсез, — диде ул, эчке ярсуын тыярга тырышып. — Аларны радиацияле кырларга язма приказсыз гына куып чыгарганнар. Ул вакытта авыл халкыннан, мәктәп балаларыннан беркем ризалык сорап тормаган, риза булмасаң, төрмәгә утырткannar. Бу эшләр дәүләт сере белән бәйле булгач, бернинди документация да алып бармаганнар, халыкның радиацияле урында эшләвен теркәп калдырмаганнар. Хәер, ул куучылар хәзер үзләре дә юк инде, үлеп беттеләр... Сезнең каршыда утырган бу хатын-кызларның барлык белешмәләре — гомер буе үзләрендә йөрткән нурланыш авыруы, яман шеш...

— Авыру хәзер бөтен кешедә дә бар ул, — дип, аны бүлдерде судья. — Бу авырулары нәкъ менә радиация тәэсирендә икәнлеген ничек исбатлый аласыз сез? Ул чакта радиацияле урыннарда эшләгәннәрен ничек исбатлый аласыз? Дәлилләрегез кайда, дәлилләрегез?

— Турыдан-туры булмаса да, мин моны читләтеп исбатлый алам, — диде Фәргать. — Чиләбе ФИБында Караболак авылы кешеләренең анализлары саклана, алар меңнән артык. Барысында да нурланыш авыруы һәм рак булган. Бу хакта аларның үзләренә әйтмәгәннәр, «гомуми авыру» дип, авылга үләргә кайтарып җибәргәннәр. Алар күптән дөньяда юк инде, ә менә больницада авыру тарихлары калган. Мин сездән сорыйм: каян килгән Караболак халкына атом нурланышы? Каян килгән менә бу каршыгызда утыра торган Караболак хатын-кызларының канында атом тамгасы? Алар бар бит! Сез сораган дәлилләрне алар үз тәннәрендә, үз каннарында йөртәләр!

Сорау бирергә чират инде «Маяк» вәкилләренә җитте.

Судьяның рөхсәте белән, ул Фәргатькә алдан әзерләп куйган соравын бирде:

— Ә сез ничек исбат итәсез аның «Маяк»тан килгән нурланыш икәнлеген? — диде ул, бик акыллы рәвештә. — Сез-

нең авыл тирәсендә, җир астында уран ятмалары булуы фаразлана, чөнки анда родон микъдары нормадан артык. Халык табигый радиацияне шуннан да алырга мөмкин. Аннан, сезнең татарлар бик актив, алар бер урында гына утырмыйлар, теләсә кайда радиациягә эләгеп, нурланыш алып кайтырга мөмкиннәр. Так что, аларның авыруларына «Маяк» сәбәпче дип, сез берничек тә исбат итә алмыйсыз бит...

Бу хәтле мәгънәсез һәм мәкерле сораудан башта хәтта Фәргать тә югалып калды. Аста калмас өчен, гаепне үз өсләренә алмас өчен атом түрәләре әллә нәрсәләргә барып җитәләр иде. Әмма Фәргатьнең бу сорауларга да җавабы бар, чөнки аның бөтен гомере шушы Караболак кешеләре белән бергә үтте бит.

— Әйе, авыл тирәсендә уран ятмалары булырга да мөмкин, — диде ул. — Чөнки Урал зонасы өчен бу табигый хәл. Әмма моңа хәтле җир астында яткан бу ятмалар беркемгә дә зыян китермәде бит, әйткәнебезчә, халык йөзгә хәтле яшәде. Халыкның читтән нурланыш алып кайтуы да ышандырмый, чөнки бу авыру белән бер тапкыр авылдан чыкмаган олылар һәм яңа туган балалар да авырый бит. Аларга кайдан килгән радиация? Болар барысы да «Маяк» эшчәнлегенең нәтиҗәсе, чөнки бу тирәдә төп радиация чыганагы булып ул тора. Мин яклый торган кешеләр барысы да «Маяк»тагы шартлаудан зарар күрүчеләр, атом пычрагын җыючылар һәм аларның ликвидатор статусын алырга хаклары бар дип саныйм. Үз вакытында хөкүмәт аларны файдаланды, хәзер ярдәмен дә күрсәтергә тиеш.

«Маяк» вәкилләре дә бу судка бик нык әзерләнеп килгәннәр иде. Чөнки мондый эшләргә юл куярга ярамый, әгәр хәзер берсен зарар күргән дип танысаң, бөтен шәһәр чиратка басачак. Ул гына да түгел, эш «Маяк»ны яптыру турында таләпләргә хәтле барып җитәргә мөмкин, чөнки халык әле бар хакыйкатьне белми, белгән очракта, ул кубарылып чыгачак иде. Шуңа күрә бүгенге суд барысы өчен дә хәлиткеч булып тора, «Маяк»ка каршы хәрәкәтне тамырыннан юк итәргә, туктатырга кирәк иде. Хәтта демократия уйнап маташкан Мәскәү дә бу мәсьәләдә атомчылар ягында иде...

— Бүген биредә «Маяк» адресына әйтелгән ямьсез сүзләр барысы да ялган, — дип башлап китте атомчыларның адвокаты. — «Маяк» — ярты гасыр буе илнең иминлеген саклап торучы калкан ул, ә монда аны нindидер монстрга әйләндереп калдырдылар. Һәм шушы сүзләрне «Маяк» төзегән шәһәрдә яшәгән, «Маяк»тан ашаган, анда эшләгән кешеләр сөйли. Әгәр «Маяк», чыннан да, сез сөйләгәнчә куркыныч булса, без монда berебез дә калмас идек инде, шәһәр дә булмас иде. Монысы сүз башы. Ә инде бу кешеләрнең

дәгъвасына килгәндә, мин шуны әйтә алам. Беренчедән, 1957 елда, «Маяк»та авария булганда, бу кешеләр анда хезмәткәр булып тормаганнар, комбинат тарафыннан бер җиргә дә атом пычрагы җыярга җибәрелмәгәннәр. Икенчедән, бала вакытларында радиацияле урында эшләүләренә аларның бернинди дә документлары, справкалары, белешмәләре юк, ә шаһәдәтлек бирүчеләр аларның туганнары. Өченчедән, аларның нәкъ менә «Маяк»тагы радиациядән зарар күрүләре һәм авырулары бер җирдә дә теркәлмәгән, болар барысы да коры сүз. Дүртенчедән, бу авылда бүгенге көндә радиацион фон нормаль исәпләнә, шул сәбәпле ул радиациядән зарар күргән торак пунктлар исемлегендә тормый, тора да алмый. Хәзер, перестройкадан файдаланып, демагогия юлы белән акча эшләп калырга теләүчеләр күбәйде, бу очрак та нәкъ шундыйга охшаган. Шушылардан чыгып, бу дәгъвачыларның таләпләрен кире кагуны, аларны канәгатьләндермәүне сорыйм.

Шулай итеп адвокат марҗа бөтенесен кирегә әйләндерде дә куйды. Ул бирегә нәкъ шуның өчен килгән иде. Аның мондый эшләр белән Чиләбедә, Свердловскида, тирә-яктагы башка шәһәрләрдә катнашканы һәм җиңеп кайтканы күп булды. Бу очракта да җиңәсенә ул шикләнмәде дә...

Үз хокукыннан файдаланып, Фәргать аңа сорау бирде:

— Менә сез, Караболакта радиацион фон нормада, дидегез. Ә бу дөреслеккә туры килеп бетми. Бу елларда Караболакта Германиядән һәм Япониядән галимнәр булып, халыкны һәм авылдагы радиацион фонны тикшереп киттеләр. Кайбер урыннарда радиация бүген дә нормадан мең тапкыр артык күрсәтә! Үзләренә кайтып, анализ ясаганнан соң, алар Караболакка «Бу йортларда яшәргә ярамый, монда үлем куркынычы яный» дигән белешмәләр җибәрделәр. Менә бу сезнең каршыда басып торган хатыннарның организмында радиация дозасы кырык алты сантизиверт булып чыкты, ә ул нормада алты гына булырга тиеш. Күрше Мусакай авылында хәтта үз тәннәрендә йөз ун сантизиверт радиация йөрткән кешеләр дә бар. Аларда каян килгән соң бу агу, «Маяк»тан булмыйча?

— Ә монда «Маяк»ның ни катнашы бар, аңлый алмыйм? — диде адвокат марҗа, чын күңелдән гаҗәпләнгән булып. — Авыл халкы, гомумән, пычрак яши, дөрес туклanмый, тәгәрәп эчә. Аларның нинди хәлдә булуларында «Маяк»ның нинди катнашы бар — шуны аңлый алмыйм мин. Ә чит ил галимнәренә аларга сенсация кирәк, Россияне зәгыйфьләндерү, коралсызландыру кирәк. Шуңа күрә сезне котырталар, төрлечә алдыйлар. Ә сез шуларның кармагына кабасыз, әле шуларның сүзләрен судта дәлил итеп китерәсез...

Бу хатынны бернәрсә белән дә җиңәрлек түгел иде. Аның үзенең бердәнбер баласы гарип булып туды, кул-аяк урынында ит кисәкләре генә иде. Ул аңа бер генә күз төшереп алды һәм башка күтәрелеп карамады. Баланы тизрәк Чиләбе гарипләр йортына алып киттеләр. Аның яңадан балалары булмады, гаиләсе җимерелде, ире китте. Ул хәзер бөтен көчен эшенә бирә, бөтен ачуын «Маяк»ка каршы эшләп йөрүчеләргә юнәлдерә, шуннан тәм, ямь таба. Ул гарипләрне, мескеннәрне, хөкүмәттән теләнеп йөрүчеләрне күралмый иде...

Фәргать тагы торып басты. Ул судның үзе китергән бер генә дәлилгә, бер генә белешмәгә дә игътибар итмәвен сизде. Алар эшне «Маяк» файдасына хәл итәргә җыеналар иде. Хәер, аның шулайрак бетәсен Фәргать үзе дә сизенде, өч-дүрт татар ничек атом монстрын җиңә алсын? Әмма бүген әйтеп, кисәтеп калырга кирәк иде, шуңа күрә дә Фәргать бу эшкә алынды.

— Бу хатын-кызларның «Маяк»тан зарар күрүләре барыбызга да билгеле, әмма сез аны танырга теләмисез, — диде ул. — Тик шуны онытмагыз: «Маяк» эшләп торганда, мондый авырулар, гарипләр бик күп булачак әле, бәлки, барысы да суд каршына килеп тә җитә алмас. Әмма шуны белеп торыгыз, үз хәлен аңлаган халык беркөнне «Маяк»ны ябуны таләп итәчәк әле! Яшиселәре килсә, меңәрләп урамнарга чыгып таләп итәчәкләр. Сез алардан инде справка-белешмәләр таләп итә алмассыз, бүгенге демагогиягез бармас алар өчен. Сезнең барыгызның да өйләрендә гарип балалар, дауналар, чирлеләр бит! Нәрсәне яклыйсыз сез?! Кемнәргә каршы көрәшәсез?! Әгәр «Маяк» эшләвен дәвам итә икән, халык беркайчан да чирдән, үлүдән туктамаячак. Менә нәрсәне күтәрергә тиеш сез, ә атом аждаһасын якларга түгел. Шуңа күрә бүген сүз үзендә бер миллиард кюри атом калдыклары саклаган «Маяк»ны яптыру турында гына барырга тиеш иде. Бу бит Җир шарын бер минутта юк итәргә җитә. Моны бүген сезгә сукыр юрист әйтә, ә иртәгә бөтен халык таләп итәргә мөмкин...

Залда утырган «Маяк» һәм хөкүмәт вәкилләре, котлары чыгып, тилегә караган кебек, Фәргатькә текәлделәр. Әле бу илдә, бу шәһәрдә, бу залда мондый сүзнең, мондый таләпнең яңгыраганы юк иде. Моны бары тик психик яктан авыру кеше генә сөйләргә мөмкин! Әмма зал тулы журналистлар, зал тулы халык, бу сүз бөтен шәһәргә таралырга мөмкин бит! Шуңа күрә ашыгыч рәвештә бу сукыр адвокатның картасын бастырырга, сүзләрен аяк астында калдырырга кирәк иде...

Чират халык яклаучысы Ткаченкога җитте.

Кирәк вакытта мәйданга тагы КГБ генералы чыкты...

Бу илдә соңгы сүзне әле һаман алар әйтә иде.

— Мин бары тик судка хөрмәт йөзеннән генә бу залда түзеп утырам, — дип башлап китте карт чекист үзенең сүзен. — Һәм мин аңламыйм, ничек итеп кеше үз мәнфәгатьләре өчен барысын да аяк астына салырга әзер — меңнәр төзегән шәһәрне дә, илне атом сугышыннан саклап калган «Маяк» комбинатын да, илнең үзен дә?! Берничә сум ташлама-льгота алу өчен кайберәүләр бүген шушыларның барысына да барырга әзер икән. Ә алар «Маяк»ның ил өчен, СССР халкы өчен нинди роль уйнаганын беләләрме икән соң? Әгәр «Маяк» булмаса, әгәр СССРның үз атом промышленносте, үз атом коралы булмаса, бәлки инде ил үзе дә булмас иде. Шул исәптән биредә утыручылар да булмас иде. Сез беләсезме соң, Бөек Ватан сугышыннан соң, Американың ракеталары СССРның егермеләп шәһәренә төбәп куелуын? Шул исәптән Чиләбегә дә? Хиросимадан соң чиратта без, совет халкы булырга тиеш иде. Әгәр СССР үзенең атом бомбасын эшләп өлгермәгән булса, алар бу һөҗүмгә бара иде. Без кыска срокта үзебезнең атом-төш коралын ясап өлгердек, бу исә Американы туктатып калды. «Маяк» биредә утыручыларның барысын да, Япониядәге кебек, атом утында янып үлүдән саклап калды. Мин моны инде бөтен кеше аңлагандыр дип уйлаган идем, ялгышканмын икән. Ничек инде үзеңне саклап торган «Маяк»ны яптырырга мөмкин? Бу бит — шәһәрне яшәүдән туктату, меңләгән кешене эшсез урамда калдыру дигән сүз. Һәм Россиянең бөтен дошманнарына үзебезне юк итәргә юл ачу. Моңа иң беренче булып шәһәр халкы каршы чыгачак, бөтен ил каршы булачак. Ә инде Караболак мәсьәләсенә килгәндә, мин ул авылны яхшы беләм. Радиация җиле, бәлки, аңа тиеп тә киткәндер, әмма юкка чыгарырлык түгел, шуңа күрә ул күчерелмәгән дә. Авыл эчкечелектән бетте, җинаятьтән, юньсезлектән бетә, бу хакта әнә муллалары да әйтте. Моны һич кенә дә тарта-суза атом белән бәйләргә ярамый. Илнең авыр хәлдә булуыннан, таркаулыгыннан файдаланып, аркага пычак кадарга ярамый. Хәер, татарларда бу бар гадәт, ахрысы, тарих шуны сөйли. Мин эшне шушы урында туктатырга, бөтенләй ябарга, мондый эшләрне алга таба карауны бөтенләй алмаска тәкъдим итәм. Чөнки бу дәүләт серен ачу гына түгел, илгә, дәүләткә каршы җимерү булып тора. Мондый мәсьәлә күтәрүчеләрнең үзләрен хөкемгә тартырга кирәк дигән катгый фикердә калам.

Әйе, Ткаченко картайгач та Ткаченко булып калган иде...

Ул КГБ генералы булмаган очракта да нәкъ шулай фикер йөрткән булыр иде. Ул бөек дәүләт, бөек милләт идеясе белән агуланган чын урыс кешесе иде. Бу юлда кемнәрдер

һәлак була, юкка чыга яки газап күрә икән — анысы инде Ткаченко өчен бик вак, әһәмиятсез нәрсә. Ул татарларны беркайчан да үткән тарих өчен кичерә алмады, аларны кешегә санамады, җай чыкканда, бу халыкны юлдан бөтенләй алып ташлау чараларын эзләде. Бу нәкъ менә шундый очрак иде...

Халык яклаучысына сорау бирергә Фәргать күтәрелде.

— Сез, КГБ генералы буларак, Татар Караболагы авылының 1957 елгы атом шартлавыннан зарар күргәнен яхшы белгәнсез. Ни өчен авылны башка урынга күчермәдегез?

— Чөнки ул күчерелергә тиешлеләр исемлегендә юк иде.

— Ялганлыйсыз, Караболак ул исемлектә бар. Сез Урыс Караболагы авылын күчергәннән соң, Татар Караболагы күчерелде дип, Мәскәүгә ялган рапорт биргәнсез. Чөнки Татар Караболагы авылы шуннан соң карталардан алып ташланган, рәсми рәвештә юк дип саналган. Илнең иминлеген саклау өчен нигә бу авыл халкы корбан булырга тиеш иде?! Җавап бирегез!

— Чөнки Татар Караболагы авылы радиациядән зарар күрмәгән. Кемдер нәрсәдер бутаган икән, алардан сорагыз...

— Ә Караболак мәктәбен кем ут төртеп яндырды? Авыл советын кем яндырды? Аларда халыкның бөтен документлары юкка чыкты бит. Иртәшнең борын төбендә булып яткан мондый диверсияләрне сез тикшерергә, белергә тиеш идегез! Әллә сезнең команда үзе ут төртеп яндырдымы, авылның юклыгын исбатлау өчен?

— Боларның эшкә нинди катнашы бар? Нигә сез барысын да бер өемгә өяргә тырышасыз? Дәлилләрегез булмагангамы?

— Безнең дәлилләребез кирәгеннән артык, әмма аларны биредә күрергә дә, ишетергә дә теләмиләр. Әле без иң соңгысын әйтмәдек — сез Татар Караболагы авылын халык өстендә атом тәҗрибәләре үткәрү өчен калдыргансыз! Сезгә этләр, тычканнар гына аз булган, сезгә сынау уздыру өчен тере кешеләр кирәк булган. Шуңа күрә күчермәгәнсез, шуңа күрә, анализларын алып, тикшереп торгансыз, әмма дәваламагансыз. Сезгә аларның радиациядән тәмам череп, газапланып үлүләре кирәк булган. Сез татарлар өстендә геноцид уздыргансыз, чөнки атом зонасында бары тик татар авыллары гына күчерелмичә калдырылган...

— Сезнең моңа дәлилегез юк! Сез моны беркайчан да исбатлый алмаячаксыз! Сез миннән бала чагыгызда авылдан сөргән өчен үч аласыз... Сез... Сез... Сез...

Ткаченко шул сүзләрен әйтеп бетермәде, авызыннан ак күбекләр чыгарып, гөрселдәп идәнгә ауды. Аның кара күзлеге читкә барып төште, аның астыннан куркыныч ике кара

чокыр карап тора иде. Ул арада картны көзән җыера башлады, ул телен чәйнәп, идәндә тәгәрәргә тотынды. Башта бу хәлдән барысы да куркып калдылар, аннан судья тиз генә тәнәфес игълан итте. Карт бераздан аңына килгән кебек булды, әмма аның сүзләре аңлаешсыз, бәйләнешсез иде. Күренеп тора, Ткаченконың акылына зәгыйфьлек килгән иде.

Ул арада «ашыгыч ярдәм» машинасы да килеп җитте.

Алар, тилергән сукыр картны алып, Сөнкүл ягына ашыктылар. Чөнки мондый авыруларны бары тик шунда гына алалар иде.

Тиле карт үзе төзеткән НКВД лабораториясенә соңгы көннәрен уздырырга китте. Бериянең тәҗрибә өстәлендә ул тиле улы белән янәшә ятачак иде...

Тәнәфестән соң бу эшне карауны туктатып торырга булдылар. Беренчедән, чакырылган шаһитлары белән шушы хәл килеп чыккан иде. Икенчедән, эш каралып бетмәгән, нәтиҗә чыгарырлык түгел. Өченчедән... Өченчедән, мондый алым, гомумән, Чиләбе судларында еш кулланыла. Бигрәк тә «Маяк» белән бәйле очракларда. Эшне карауны айдан айга, елдан елга күчереп йөрткән арада, дәгъвачылар үлеп тә китә. Чөнки бу мәсьәләне күбрәк авыру кешеләр кузгата, суд юлларында еллар буе йөри торгач, алар тын гына теге дөньяга күчәләр...

Иртәш судьясы да шуңа өмет итте. Чөнки бу дәгъвачы хатыннарның барысы да авыру, адвокатлары чирле, барысы да рак белән хисапта торалар. Димәк, аларның да көннәре санаулы. Судны башта көзгә күчерерләр, аннан — кышка, аннан — җәйгә. Шулай итеп, вакыт барысын да хәл итеп куячак. Ә анда барып яту өчен суд карары кирәк түгел инде...

Судтан соң барысы да җыелып Гөлҗиһаннарга кайттылар. Шәһәр капкасыннан чыгарга әле бераз вакыт бар иде, шуңа күрә өйгә кайтып, бераз ял итеп алырга булдылар. Фәргатьнең дә хәле начарланып киткән иде, Гөлҗиһан үзе дә аягында чак басып тора. Әле ярый ярдәмгә Таифә җиңгәсе, Сөнкүлдән Җәүһәрия түти килеп җиттеләр, өйдә Гөлҗиһанның кулына эш тидертмәделәр. Таһирҗан карт белән Хәбирә карчыкны Караболакка кайтарып куярга машинасы да табылды, Иртәштә яшәүче авылдашларыннан берәү үзе тәкъдим итте.

Чәй эчкәндә дә сүз гел суд турында булды. Халык «Маяк» вәкилләренең һәм Ткаченконың үз-үзләрен тотышларыннан телсез калган иде. Нинди генә гаепләүләр ишетмәделәр алар бүген үзләренә карата! Алар илне җимерүче икән, атом сугышына юл ачарга җыеналар икән, эчеп үләләр икән, һәм

башкалар, һәм башкалар. Әлбәттә, аларга дөреслек кирәк түгел иде, аларга Караболак халкының дәшмәве, тизрәк үлеп бетүе кирәк иде. Аларның авыл халкы өстендә атом тәҗрибәсе уздырулары турында әйткәч, КГБ генералын көзән җыера башлады бит! Димәк, сөяленә бастылар, хаклыкны ишетеп тартышты карт урыс…

— Мин аны шундук таныдым, — диде Таһирҗан карт. — Караболак халкын сөргенгә сөрүче дә, атом зонасында үләргә калдыручы да шушы бәдбәхет бит. Ни йөзе белән килгән ул безнең янга судка? Хәер, Аллаһы Тәгалә аңа барысын да ишеттерде, безнең авыз белән. Ул барысын да белеп китте. Һәм тереләй җәзасын алып китте.

— Теге вакытта мин аны яхшы хәтерләп калдым, — диде Фәргать тын гына. — Елкылдап торган хром итек, билдә наган, башта йолдызлы биек фуражка. Мин әтине сугыштан шундый кыяфәттә кайтыр дип көткән идем. Ул безне авылдан генерал киемендә куган булган икән.

— Хәзер калган гомерен тиләләр киемендә уздырыр инде, психбольницада, — диде Гөлҗиһан кискен генә. — Кешегә кое казысаң, үзең төшәсең ул.

Алга таба судка ничегрәк әзерләнергә киңәшеп алдылар.

Көзгә кадәр әле вакыт шактый иде, һәм алар судья таләп иткән барлык белешмәләрне дә эзләп карарга булдылар. Әлбәттә, бу мөмкин хәл түгел иде, чөнки аларны колхоз кырына эшкә чыгару турында приказлар булмаган да, сакланмаган да, әмма табарга кирәк. Алар организмындагы радионуклидларның нәкъ менә «Маяк»тан таралганлыгын исбатларга кирәк. Аларның башка нәрсә тәэсирендә түгел, нәкъ менә шул радиация аркасында чирләүләрен исбатларлык белешмәләр кирәк. Димәк, тагы эзләнергә. Бу инде аларга ниндидер ташлама-льготалар өчен дә кирәкми, дөреслекне торгызу өчен кирәк. Караболак халкының йөзенә ягылган пычракны юу өчен кирәк. Атомчыларны аз булса да авызлыклау, котырып корал җитештерүләрен туктату өчен кирәк. Әмма берничә татар моны эшли алырмы — анысы Аллаһ кулында иде. Ә адәм баласы хәрәкәт итәргә, сәбәбенә керергә тиеш.

Фәргать белән Гөлҗиһанның хәлен күргәнгә, авылдашлары карт белән карчыкны үзләре генә кайтарып килергә булдылар. Улларын күрәселәре килсә дә, ата белән ана Иртәштә калдылар, чөнки икесенә дә ашыгыч рәвештә дәваланырга кирәк иде. Гөлҗиһан әле бүген иртә белән генә улы белән күреште, аның исәнлеген күреп бик сөенде. Баһадур бөтенләй икенче кешегә әйләнгән анда, Таһирҗан бабасы белән намаз укый башлаган, әбисенә бөтен йорт эшләрендә булыша, япон галимнәренә ярдәм итә.

— Сез Баһадурга күз-колак булыгыз инде, әби, — диде Фәргать, карт белән карчыкны юлга озатканда.

— Ул үзе безгә күз-колак, улым, — диде Хәбирә карчык. — Бөтен авыл шакката аңа. Белмәгәне юк баланың, күз генә тимәсен. Намазын да укый, өйдә дә булыша, рәхмәт яугыры.

— Баһадур нәселнең йөз аклыгы ул, милләтнең соңгы әүлиясы, — диде Таһирҗан карт. — Һәм барыбызның да догачысы. Бик тиз Коръәнгә кереп китте. Өйдә инде укымаган дини китабы калмады. Шушы баланы күрер өчен генә дә йөзгә хәтле яшәргә була иде…

Фәргать белән Гөлҗиһанга уллары турында шундый матур сүзләр ишетү бик күңелле булды. Бигрәк тә авылның әүлиясы Таһирҗан бабай исеменнән. Инде Ходай ул балага хәерле гомер бирсен дә көтелмәгән бәла-казалардан сакласын.

Таһирҗан карт белән Хәбирә карчык Иртәштән чыгып китәргә ашыктылар, чөнки билгеләнгән вакыт җитеп килә иде. Гомерендә авылдан чыкмаган, шәһәр күрмәгән Хәбирә карчыкның Иртәшкә исе китте. Гөлҗиһаннарның тәрәзә каршында гына диңгездәй күл җәйрәп ята, якында гына урман шаулап утыра. Шәһәр эчендә дә яшеллек күп, бөтен җирдә чәчәкләр. Урам тулы халык, берсеннән-берсе матур киенгәннәр, бер дә чирлегә охшамаганнар. Хәер, чирләләре өйдә ятадыр инде аның, йә больницада…

— Моның атом бомбасы кайда соң, кызым? — дип сорады Хәбирә карчык үзләрен озата чыккан Гөлҗиһанга. — Бөтен җирләре ялт иткән, бер куркыныч нәрсә дә күренми бит.

— Аның бомбасы менә синең аяк астыңда инде, Хәбирә килен, — дип җавап бирде аңа Таһирҗан карт. — Андый кара эшләр җиде кат җир астында эшләнә ул.

— Әнә күлнең аргы ягында утлы төтен баганалары күрәсеңме, әни? — дип сүзгә кушылды Гөлҗиһан да. — Шунда хәтле барып җитә ул җир асты заводлары. Аларның игечиге юк. Кыскасы, өстә — җәннәт, аста — җәһәннәм.

Бөтен авылдашлар, җыелып, Таһирҗан карт белән Хәбирә карчыкны озатып калдылар. Бу юлы аларны шәһәр капкасында да озак азапламадылар, чөнки монда керүгә караганда чыгу җайлырак иде. Иртәштән чыгуга, җиңел машина каен урманнары, зәңгәр күлләр яныннан Караболакка таба җилдерде. Әле иртә белән генә авылдан чыгып киткән карт белән карчыкка алар башка дөньядан кайтып киләләр кебек тоелды. Иртәшләре никадәр матур кебек тоелса да, аларга үз Караболаклары якын һәм кадерлерәк иде. Алар аны инде сагынып та өлгергәннәр иде. Дөньяда алар өчен Караболактан да матур, изге, газиз урын юк иде.

## Унберенче бүлек

Бу җәйдә Караболакка тагы япон галимнәре һәм студентлары килде.

Аларны узган ел, «шпион» дип, Чиләбедән авылга җибәрмичә тилмерткәннәр иде, бу юлы инде алар шымчы түгеллеккә махсус белешмә алып килгәннәр. Ягъни барысы да үзләре укый яки эшли торган уку йортларыннан юлламалар алганнар. Алар биредәге экологик хәлнең, радиациянең ни дәрәҗәдә икәнлеген яхшы беләләр, шуңа карамастан тикшерүләрен дәвам итәргә уйлаганнар. Иң беренче чиратта, аларны да радиациянең кешеләргә тәэсире кызыксындыра булып чыкты. Даими нурланыш алып торган кешеләрнең акыллары ничек үзгәрә, алар нинди авыруларга тизрәк бирешәләр, нинди гайре табигый хәлләр күзәтелә, мутация нинди гариплек очраклары бирә — аларга барысы да кирәк иде. Ә Караболакта андый хәлләр һәр йорт саен, Караболак бөтен дөнья галимнәре өчен әзер лаборатория, тәҗрибә мәйданы булып тора ала.

Япон галимнәре бу ике килүләрендә шуны да ачыкладылар: авыл халкының бер өлеше радиациядән чалгы белән чапкандай кырылса да, биредә туксанга, йөзгә җиткән кешеләр дә бар. Һәм, иң гаҗәбе — кешеләрдә яшәү дәрте бик көчле! Нинди авыру, авыр хәлдә булсалар да, алар кояш белән бергә торалар, кояш белән яталар. Алар гел аяк өстендә, гел хәрәкәттә. Авылда укыган кешеләр күп, һәр йорттан диярлек югары белемле берәр кеше чыккан. Дөрес, алар хәзер барысы да читтә инде, зур шәһәрләрдә, әмма барысы да хезмәттә, берсе дә үлем көтеп ятмый! Үзләрендә генетик яктан җимергеч атом тамгасы йөртсәләр дә, аларда яшәү дәрте сүнмәгән, өмет бетмәгән.

Галимнәр шуңа да игътибар иттеләр — иң авыр хәлдә урта буын вәкилләре иде. Болар — «Маяк» шартлаганда бала яшендә булган кешеләр, аларның сөякләре, каннары, тәннәре бөтен радионуклидларны үзләренә җыйган, аннан балаларына тапшырган. Биредә инде өченче буын атом тамгалылар үсеп килә, авылда мутантлар, гарипләр, тиленәр арткан. Япон галимнәре бу хәлләрне үзләрендә булган атом фаҗигасе нәтиҗәләре белән чагыштырып өйрәнделәр. Хиросима һәм Нагасакида атом бомбасы шартлаганнан соң, йөз меңгә якын япон тереләй янып үлгән иде. Аларда да исән калганнар арасында тилерү, яман шештән үлү, гарипләнү очраклары шактый булды. Ил бу милли фаҗигадән бик авырлык белән һәм озак еллар чыкты. Әмма барыбер аякка басып, кеше булып кала алды. Милләттәге сабырлык, акыл, гыйлем бу яраларны төзәтергә ярдәм итте. Дөрес, Япониядә бү-

ген дә көчле радиация нәтиҗәсендә нәселсез калган, яман чирдән интеккән, генетик яктан зур үзгәрешләр кичергән кешеләр шактый, әмма алар биредәге кебек хәлдә түгел. Япон галимнәре һәм табиблары бу юнәлештә бик нык эшләделәр, атом афәте кичерүчеләрнең хәлләрен җиңеләйтү өчен берни дә кызганмадылар. Бүген Япониядә фән, медицина шулхәтле югары дәрәҗәгә куелган ки, монда һәр кеше, аның һәр күзәнәге хисапта, күзәтүдә тора, махсус ярдәм ала, дөньядагы иң соңгы ачышлар ярдәмендә дәвалана. Иң мөһиме — кеше биредә үзен кадерсез һәм кирәксез итеп хис итми. Радиация нәтиҗәсендә авырган кешеләргә, аларның нәселләренә карата дәүләт аерата игътибарлы һәм ярдәмчел. Дәүләт аларны теләсә кайсы илгә үз хисабына җибәреп дәвалый, бу кешеләрне бәхетле итү өчен бөтенесен эшли.

Ә биредә, Россиядә... Урал артындагы бу татар җирләрендә...

Япон галимнәренең әле беркайда да кешегә карата мондый кадерсезлек һәм игътибарсызлык күргәннәре юк иде. Урыс дәүләте бу татарларны менә инде ярты гасыр атом радиациясе белән агулый. Аларны үле зоналарда махсус калдырып, үзенең тәҗрибә максатларында файдалана. Ә үзләренә бернәрсә бирми, ярдәм итми! Яман шешнең иң соңгы чигенә килеп җиткән авыруларның хәтта бер төймә дарулары да юк! Авылда больница юк, күрше авылдан килеп йөрүче фельдшерның кулында мондый авыруларга ярдәм итәрлек берни юк. Районда аларны якын да җибәрмиләр, шәһәр больницаларында үләргә ятар өчен чират... Мондый шартларда исән калу, яшәү өчен, чыннан да, таш, тимер булу кирәктер. Ә алар — кешеләр бит. Әгәр Япониядә шушындый хәл булса, нурланыш алган кешеләрнең нәселләре күптән беткән булыр иде инде... Бу хәтле газаплы, авыр тормышны алар алып бара алмаслар иде...

Шуңа күрә японнар бу авыл татарларын бик кызгандылар, аларга кулларыннан килгәнчә ярдәм итәргә тырыштылар. Алар бу юлы үзләре белән иң яхшы дарулар алып килделәр, авыруларга шунда ук диагноз куярга, анализлар ясарга иң яхшы япон аппаратларын кулландылар, кирәк булганда, халыкка беренче ашыгыч ярдәмне дә күрсәттеләр. Әмма аларның төп максатлары фән белән бәйле булганга, алар, нигездә, радиациянең кеше организмына тәэсирен өйрәнделәр.

Баһадурга алар беренче күрүдә үк игътибар иттеләр. Үзенең алыптай зур гәүдәсе, гаҗәеп матур, нурлы йөзе белән ул бөтен кешене үзенә җәлеп итеп тора иде. Әйтерсең лә ул авыру, гарип кешеләр арасына бөтенләй башка дөньядан, башка планетадан килеп эләккән. Бу балага әле унике яшь тә тулмаганын, аның инде урта мәктәп тәмамлавын һәм гаҗәеп зирәк акылга ия булуын белеп, японнар сүзсез калдылар.

Бу — нәкъ алар эзләгән, алар өйрәнергә тиешле яңа тип кеше иде. Малай алар белән шунда ук инглиз телендә яхшы итеп сөйләшә башлады. Ул алар белән теләсә нинди җитди темага сөйләшә алырлык әзерлектә иде. Японнар бигрәк тә аның фән-техника, радиобиология, медицина өлкәсендә күп белүенә таң калдылар, бу татар баласы белгәннең кайберләрен әле алар үзләре дә белми иде. Тиешле шартлар тудырсаң, бу бала дөньяга бөек ачышлар ясарга сәләтле зур галим булачак иде. Һәм японнар аны ничек тә үзләре белән алып китү максаты куйдылар, аны укытырга, акылын дөнья өчен файдаланырга кирәк иде. Ә бу илгә, Россиягә, күренеп тора, ул үзе дә, аның ата-аналары да, милләте дә кирәк түгел...

Әмма аларны бер нәрсә туктатып тора: бу татар баласы, алардан аермалы буларак, дөньядагы барлык нәрсәне дин белән, Аллаһның кодрәте белән бәйләп аңлата. Малай үзенең яшәү рәвеше итеп ислам динен алган. Яшәүгә генә түгел, үлемгә дә аның шул күзлектән, тыныч һәм сабыр каравы япон галимнәрен тетрәндерде, уйланырга мәҗбүр итте. Бу хакта аның үзеннән сорагач, Баһадур:

— Иннә лилләһи вә иннә илайһи раҗигуун, — дип җавап бирде.

Японнар аңламыйча бер-берләренә караштылар. Баһадур аларга Коръәннең бу аятен инглизчә аңлатып бирде:

— Барыбыз да аннан килгәнбез һәм яңадан Аллаһка кайтабыз, — диде ул, инглизчәгә гарәп, япон, татар сүзләрен дә кушып җибәреп. — Ягъни, без әле туганчы ук, илле мең ел алдан, Аллаһ үзенең нурыннан безнең җаннарыбызны барлыкка китергән. Җан исә Аллаһка гына буйсынып яшәргә ант иткән. Без, Аллаһ хозурында торып, җиргә иңүебезне, үзебез өчен билгеләнгән тәнгә керүебезне көткәнбез. Тәкъдир буенча ата-аналарыбыз очрашып кавышкач, аналарыбыз карынында ятканда, безгә җан иңгән. Ягъни, Аллаһ рәхмәт фәрештәләрен җибәреп, карындагы балага тәкъдирен билгеләгән һәм җан биргән. Без туганчы ук инде Аллаһ өчен безнең язмышыбыз билгеле булган. Ягъни кешенең бөтен гомере, язмышы, бәхете, авырулары, хәтта кайчан ничек үләсе дә шушы тәкъдир кодында язылган булган. Сез аны генетик код дисез... Әмма кеше моны үзе белмәгән. Кеше үзе өчен билгеләнгән гомерне үзе теләгәнчә яшәп бетергән. Бик азлар гына Аллаһ теләгәнчә яшәгәннәр...

— Ә кешеләр каян белергә тиешләр соң ничек яшәргә кирәклеген?— дип сорап куйды карт япон галиме. — Ул бит үзенең тәкъдирен белми, белсә дә, аны төзәтә алмас иде, чөнки ул алдан язылган, дисең бит...

— Аллаһ кешене барлыкка китерү белән, аның яшәү программасын да билгеләгән, — дип дәвам итте Баһадур, карт

галимнең кызыксынуына сөенеп. — Әйтик, сезнең менә бу япон аппаратларын эшләтеп җибәрү өчен аларның иструкцияләрен белергә кирәк, шулай бит? Ватылса, төзәтү өчен схемасын белү кирәк. Кеше белән дә шулай ук — аның да үз инструкциясе бар, Аллаһ аларга дөрес яшәү программасын биргән, күрсәткән. Ул һәр заманда, һәр кавемгә үзенең пәйгамбәрләрен, изге китапларын, күрсәтмәләрен биреп торган, шулар аша кешеләрне дөрес яшәргә өйрәткән. Адәм балалары үзләренә һәм башкаларга зыян салырга тиеш булмаганнар. Чөнки бар дөнья, шул исәптән кеше үзе дә — Аллаһ бүләге, аның нигъмәте, әманәте. Кеше боларны заман ахырына хәтле сакларга тиеш. Аллаһны бар дип һәм бер дип белгәннәр шулай яшәгәннәр дә, ә күңел азгынлыкларына бирелгәннәр бу кисәтүне онытып, үзләренчә яши башлаганнар. Алар байлыкка, дан-дәрәҗәгә, төрле зиннәтләргә табынганнар, ягъни шулар хакына яши башлаганнар. Аллаһның «Дөньяга һәм кешеләргә зыян салма» дигән кисәтүе онытылган. Бу дөньяда яшәвебез өчен Аллаһка рәхмәт әйтү онытылган. Һәм шуның нәтиҗәсе — менә бүгенге көн, бүгенге тормыш. Кешелек үзенең бетүенә таба бара. Кыямәт көнендә безнең җаннарыбыз тагы тәннәребезгә керәчәк һәм бу дөньяда кылганнар өчен Аллаһ каршында җавап бирәчәк. Аллаһ җаннарның хәтеренә Үзенә биргән антны төшерәчәк. «Сиңа гына буйсындык» дигән антларын. Бу дөньяда кылган гамәлләренә карап, теге дөньяда кешеләрне мәңгелек җәннәт яки мәңгелек җәһәннәм көтә. Менә без бу дөньяга шушы сынауны үтәр өчен җибәрелгән инде. Кешеләр җирдә үк җәннәт һәм җәһәннәм белән сынала. Боларны белгәннән соң, күп нәрсә вак һәм әһәмиятсез булып кала. Менә шуңа күрә мин яшәү һәм үлемгә тыныч карыйм.

Баһадурның шушы сүзләреннән соң мәктәп ишегалдында шомлы тынлык урнашты. Бу авыл халкын коткарабыз, аларга ярдәм итәбез, дип килгән японнар, уңайсызланып, берберләренә караштылар. Урал артындагы караңгы бер авылда әле уникесе дә тулмаган бер татар баласыннан монда бу сүзләрне ишетербез дип алар уйламаганнар да иде. Японнар — дин мәсьәләсендә бик тыныч халык, аларда нинди дин тотсаң да — ирек. Әмма бу баланың сөйләгәннәре янында теге диннәр уенчык кебек кенә күренә, күңел юаткыч, мавыгу гына булып тоела. Җаннарның яратылышы, аларның җиргә иңүләре, билгеләгән вакытта тәндә яшәүләре, җирдәге гомерләре беткәч, яңадан күккә ашулары, кыямәт көнендә Аллаһ алдында җавап тотачаклары шулхәтле ачык булып күз алларына килеп басты, аларга хәтта куркыныч булып китте. Һәркем үзе турында уйлады, үзенең нинди хәлдә каласы турында уйлады.

Японнар күрә иде — бу малай башкалар кебек табигый бала түгел, ул беркемгә дә охшамаган. Аның җаны да, акылы да, хәтта тән төзелеше дә башкаларныкы кебек түгел. Ул үз яшьтәшләренә караганда күпкә зур, гәүдәле, аңа карап, егерме-егерме биш яшьләрдәге егет дип әйтеп була. Акылы компьютерларны алыштырырлык, ул үзенең башында физика-математика кануннарын да, чит телләрне дә, атом төзелешен, радиобиология серләрен дә тотып тора. Ә җаны. Җаны гаять нечкә, чиста, ихлас бу баланың. Анда кернең, каралыкның, явызлыкның эзе дә юк. Кайдан килгән аңа шундый холык, акыл, иман? Бу ата-бабаларыннан калган нигъмәтме, нәселдән килгән милли байлыкмы, әллә радиация кешеләрнең акылына шундый да тәэсир ясый аламы? Әллә соң болар барысы да Баһадур үзе сөйләгән Аллаһның бер хикмәтеме, могҗизасымы? Бу яшьтә адәм баласы моның хәтле нәрсәне белә алмый, аның башы бу хәтле мәгълүматны сыйдыра алмый, җаны бу хәтле нечкә тоемламый. Дөньяны күргән зур галимнәргә ул әнә шулай көчле тәэсир итте. Әмма каян килә бу балага мондый көч — күктәнме, җирдәнме, монысына әле япон галимнәре үзләре дә җавап таба алмадылар. Чөнки аларның иң төгәл аппаратлары да моңа җавап бирерлек түгел иде.

Баһадурның йөз яшьлек бабасы белән бергә көнгә биш вакыт намаз укыганын да белгәч, галимнәр тагы гаҗәпкә калдылар. Малай гамәлләрендә дә сөйләгәненчә яши иде. Аның тормышка карашы гына түгел, яшәү рәвеше дә бөтенләй башка төрле. Сынауны ул менә шушы рәвештә үтә иде. Гадәттән тыш акылга ия булган баланың башка дөньяда яшәргә ничек җитди итеп әзерләнүен күреп, галимнәр уйга калдылар. Чөнки ул алар белмәгәннәрне белә иде.

Малайга карап бер гаҗәпләнсәләр, аның йөз яшьлек бабасын күреп, тагы да нык аптыраштылар япон галимнәре. Йөз яшьлек картның йөзендә ник бер җыерчык булсын! Аның битләре онытынык кебек шоп-шома, нур чәчеп ялтырап тора. Әйтерсең лә авылны басып киткән әҗәл чире аңа бөтенләй кагылмый, әйтерсең лә ул үлемсез! Иң гаҗәбе — картның чәчләре яңадан карала башлаган, сакалы да каралып килә. Япон галимнәренең мондый хәлне әле беркайчан да күргәннәре юк иде. Шушы ике кеше яшәгәнгә генә күрә дә, Караболак авылы аларга могҗиза булып тоелды. Кешелекнең бу серен ачар өчен алар күп нәрсәләр бирергә әзер иделәр. Һәм алар татарларның тормышын тагы да ныграк өйрәнә башладылар.

Караболак авылы алар уйлаганга караганда да борынгырак булып чыкты. Бу юлы аларга борынгы курганнарны да күрсәттеләр, аларга кимендә биш-ун мең ел бар иде. Ни га-

җәп, авыл халкы биредә кемнәр ятканын яхшы белә, безнең ханнарыбыз, диләр. Баһадурның сөйләвенчә, Караболак халкы бик борынгы Алып Ханнар нәселеннән киткән икән. Ә алар бирегә туфаннан соң килеп чыкканнар, дөресрәге, зур су үткәч, Урал тауларыннан төшкәннәр. Алар гаҗәеп зур гәүдәле, утыз метр озынлыктагы гигантлар булганнар. Бу тирәдә зур шәһәрләр төзеп, кодрәтле дәүләтләр тотып яшәгәннәр. Бүгенге татарлар шулар нәселеннән киткән икән. Алар үзләрен Нух пәйгамбәрнең варислары дип йөртәләр, борынгы пәйгамбәрләр һәм әүлиялар нәселеннән икәнлекләрен беләләр. Урал тавының ике ягына да менә шушы татарлар таралган. Бу аларның Аллаһтан бирелгән җирләре булган.

Баһадур аларны Аллакүл чишмәсенә дә алып барды, тау куышына алып кереп күрсәтте. Кимендә илле мең еллар элек биредә кешеләр яшәгәнгә охшый иде. Японнар Алып Адәмнең ташка уелып калган эзләрен фотога, видеога төшерделәр, нидер үлчәделәр, тикшерделәр. Аларны бигрәк тә зәңгәр балчык белән чишмә суы бик гаҗәпләндерде, чөнки, бер яктан, аларның составында радиоактив радон булса, икенче яктан, башка радиоактив матдәләрне юк итә торган элемент та бар иде. Аларның мондый сәер составны әле беркайчан да, беркайда да очратканнары булмады. Алар шулай ук Таһирҗан картның гомер буе шушы суны эчкәнен белделәр, әмма, Баһадур әйткәнчә, ул аны өшкереп эчә икән. Баһадур аны японнарга эшләп тә күрсәтте. Бер караганда, бик җиңел кебек. Әмма бу суның файдасы булсын өчен, башта Аллаһка ышанырга һәм ул әйткәнчә яшәргә кирәк икән. Ул бары тик шундыйларга гына ярдәм итә, ди. Авыл халкы элеккеге заманнарда барысы да шулай яшәгән, дин тоткан һәм йөз илле яшькә хәтле җиткән. Татар халык иҗатына, әкиятләренә мондый су «тере су» яки «мәңгелек су» булып кереп калган, аның дөньяда барлыгына ышанганнар, аны эзләгәннәр. Татарларның Хозыр Ильяс дип йөрткән изгеләре бу суны эчкән һәм үлемсез булган дип сөйлиләр Караболакта. Ул хәзер дә авыр хәлдә калган кешеләргә килеп ярдәм итә икән. Ап-ак сакаллы карт булып юлларына чыгып баса, ди.

Боларны белгәннән соң, Караболакның гади авыл булмавына япон галимнәре тагы бер кат инандылар. Шуңа күрә биредә Таһирҗан карт һәм Баһадур кебек могҗиза ияләре яшәвенең сәбәбен алар аңлый башладылар. Чөнки алар кешелекнең башында торучылар токымыннан иде. Һәм аларга башкаларда булмаган нәрсәләр салынган иде.

Ә Караболак үзенчә яшәвен һәм яшәү өчен көрәшен дәвам итте...

Чернобыль вакыйгаларыннан соң мондагы халыкның да күзе ачылды, алар үзләренең ни өчен шушы хәлгә калуларын аңлый башладылар. Гөлҗиһан да аларга барысын да кайтып аңлатып, төрле җирләргә хатлар язып, имзаларын җыеп җибәреп торды. Бу чорда Караболакның үзенә дә нинди генә түрәләр, нинди генә депутатлар, галимнәр, журналистлар килеп китмәде! Чиләбедән дә, Мәскәүдән дә, хәтта чит илләрдән дә килеп тордылар. Әмма авыл халкы, күпме йөрсә дә, үзләренең радиациядән зарар күрүен исбатлый алмады. Авыл клубында нинди генә җыелышлар уздырып карамадылар, анда гына сыймагач, урамнарга чыгып, зур җыеннар уздырдылар, бөтен җиргә хатлар, мөрәҗәгатьләр яздылар — файдасы булмады. Барысыннан да бертөрле җавап килә — юк, Татар Караболагы авылы радиациядән зарар күрмәгән икән. Зарар күрмәгәч, ярдәм дә юк. Шуның белән бетте-китте. Мөслим авылындагы кебек, халык шулай бер ярсып күтәрелде дә, мәгънә булмагач, тынып калды. Чөнки мөслимлеләр дә, радиациядән зарар күрүләрен закон нигезендә исбат итә торып, әллә нәрсәгә ирешә алмадылар. Авыл һаман үз урынында тора, кешеләр шул үле җирдә яшәп яталар, шулай ук кырылалар, үләләр. Судлашып хөкүмәттән алган ярдәм акчасы бер уч даруга да җитми. Шулай булгач, йөрәк бозып йөрүдән ни мәгънә? Күпләр инде әнә шулай дип уйлый иде.

Караболак халкы тагы үз тормышына кереп батты. Җәен шул агулы болыннарда печән чапты, заманында тыелган урманнарда утын әзерләде, атом калдыклары йөзеп йөргән суда мал-туарын эчерде. Чөнки аның яшәр өчен башка җире, башка урман-болыннары, башка елга-сулары юк иде. Көзләрен исә, нәкъ элеккечә итеп, малын суйды, каз өмәләре үткәрде, шаулатып туйлар ясады. Кышын бераз ял итте, буранлы көннәрдә кар көртләре белән көрәште, йорт-җирен, мал-туарын саклады. Балалар берәм-сәрән булса да мәктәпкә йөри торды, олы як мәчеткә барып гыйлем алды, намазын укыды. Радиация дип тормады, балалар туа торды, аякка баса торды, дөньяга тарала торды. Тууга ияреп, үлем дә килде, әмма Караболак халкы аңа ияләшкән иде инде. Болардан зур фаҗига ясамыйча, барысын да сабырлык белән кабул итәргә өйрәнделәр. Алар инде атом казаны өстендә дә яшәргә һәм исән калырга өйрәнеп киләләр иде. Шуңа күрә һәр сәламәт көннең кадерен белергә тырыштылар, зарланмыйча гына үз тормышларын үзләре өстерәделәр.

Караболакның шушы бер көйгә салынган тыныч тормышы Баһадурга да тәэсир итте, ахры, ул авылга кайткач терелеп киткән кебек булды. Һәрхәлдә, ул биредә үзенең авыруларын беразга онытып торды. Аның инде башы да алай әй-

ләнми, авызы да кибеп интектерми, борыны да канап азапламый. Ул Караболакта бөтенләй яңа, чиста дөньяга чумды. Бер яктан, дин белән аның күңеле сафланса, икенче яктан, авылга килгән япон галимнәре аңа яңа дөнья ачтылар. Аларда булган техник җиһазларны, аппаратураларны күреп, Баһадур шаккатты. Дөрес, аның үзенең дә Иртәштә кечкенә генә иске компьютеры бар иде, әмма японнарныкы бөтенләй башка. Алар аша бөтен дөньяга чыгарга, элемтәгә керергә була икән! Ул үзе кечкенә генә, кулга күтәреп йөри торган, ә үзендә күпме мәгълүмат! Ул үзе интернет дип аталган бөтендөнья челтәренә тоташтырылган икән, хәбәрең бер мизгел эчендә бөтен дөньяга тарала... Һәм үзең дә аннан дөнья хәтле яңа мәгълүмат ала аласың — дин буенча да, фән буенча да...

Баһадур буш вакытларында япон галимнәренең рөхсәте белән аларның компьютерында интернетта утыра башлады. Ул дин һәм фән буенча үзен кызыксындырган бик күп яңа мәгълүмат туплый алды. Бераз шомаргач, ул тәвәккәлләп үзе дә дөньяга хәбәрләр җибәреп карый башлады. Ислам дине турында японнарга сөйләгәннәрен, бер калыпка салып, ул интернет челтәренә кертеп җибәрде. Хәбәрләрен ул бик иркенләп, берничә телдә язды. Тиздән аңа да җаваплар килә башлады, кем рәхмәт әйтте, кем аны фанатиклыкта, тилелектә гаепләде, рәхәтләнеп яшәп калырга өндәде. Әмма Баһадур боларга игътибар бирмәде, көне-төне язуын, дөньяга ислам дине турында үзе белгән хәбәрләрне таратуын дәвам итте.

Баһадурның дөньяга чыгарырга теләгән икенче темасы — атом һәм радиация турында иде. Аның Урал таулары артында булып яткан фаҗигале хәлләр турында дөньяга хәбәр бирәсе килде. Бигрәк тә бөтен дөньяга үлем куркынычы янаган «Маяк» атом берләшмәсе турында, даими радиация астында яшәргә мәҗбүр булган татар авыллары, Караболак турында хәбәр биреп каласы килде аның. Дин турында язганда бик катнашмасалар да, аның тыелган темага керүен белүгә, дөньяга «Маяк» турында хәбәрләр җибәреп ятуын аңлауга, күзгә күренмәгән органнар да эшкә керәште. Алар Баһадурның һәр язганын ялганга чыгарып бара башладылар, үзен авыру тилегә әйләндереп, интернетта исемсез хатлар урнаштырдылар. Ткаченко үләргә ятса да, аның командасы үлмәгән, ул һәр дөрес сүзгә чәчрәп каршы чыгарга һәм һәр намуслы кешене пычратып ташларга әзер тора иде.

Үсмер баланың әле гомерендә мондый мәкерне, алдауны күргәне юк иде, шуңа күрә баштарак ул югалып калды. Аннан бөтен дөнья алдында Россиядәге кара көчләр белән бәхәскә керде, көрәшкә чыкты. Исемсез хатлар артындагы кешеләр Урал аръягындагы татар авылларының, шул исәптән

Караболакның да бернинди фаҗига кичермәүләрен, аларның гөрләтеп яшәп ятуларын исбатларга тырыштылар. Бала Баһадур исә киресен язды, башканы исбатлады. Органнар Иртәш тирәсендәге табигатьнең бик чиста булуын, мондагы экологик хәлне дөнья галимнәренең тикшереп торуын әйттеләр, Баһадур исә киресен язды. Ул, кулында булган бөтен дәлилләр белән, бу тирәнең дөньяда иң пычрак урын икәнлеген исбатлады, шул хакта космостан төшерелгән рәсемнәрне урнаштырды. Чиләбе өлкәсе тоташы белән төтен, тоташы белән кара тап иде. Органнар «Маяк» берләшмәсеннән беркемгә бернинди хәвеф янамый, анда барысы да тиешле тәртиптә, дип, кешеләрне ышандырырга тырыштылар. Ул биредә бер миллиард кюри атом калдыклары саклануын, аларның даими рәвештә суга, һавага, туфракка таралып ятуын, шул сәбәпле бөтен тирә-якка коточкыч зыян килергә мөмкин икәнлеген исбатлады. Ул гына да түгел, Иртәштәге атом эшчәнлеге аркасында ул кешелеккә зур куркыныч янавы турында кисәтте. Бу хакта Баһадурда мәгълүмат җитәрлек иде, һәм ул әйтеп өлгерергә тиеш иде. Органнар белән бәхәсләшеп ятуның мәгънәсез вакыт уздыру икәнлеген ул вакытында аңлап өлгерде, алар аны шуңа махсус тартып керткәннәр иде. Һәм Баһадур, бөтен бәхәсләрне бер читкә куеп, кешеләргә, төрле илләрнең парламентларына үзенең төп мөрәҗәгатен, хатын язды. Дөнья бу хәлләрдән гыйбрәт алырга тиеш иде.

— Мин — Баһадур Фәргать улы Зөлкарнәй, беренче совет атом бомбасы ясалган Иртәш шәһәрендә тудым, — дип башлый ул һәр кичне интернетта үзенең хәбәрләрен. — Мин хәзер әти-әниемнең туган авылы Татар Караболагыннан сезгә мөрәҗәгать итәм. Без биредә атом базында яшәргә мәҗбүрбез. Бу тирәләр менә илле ел инде көчле радиация тәэсиренә дучар ителгән. Татар Караболагында дүрт мең кешедән нибары җиде йөз кеше исән калды, аларның да туксан проценты рак белән авырый. Авылда шулай ук гарипләр, мутантлар, дауналар да күп. «Маяк» атом берләшмәсе тирәсенә урнашкан башка авылларда да шушы ук хәл — гарипләр һәм мутантлар. Атом казаны өстендә утырган Иртәшнең үзендә җитмеш процент психик яктан тайпылышлы кешеләр яши. Бу фән белән исбатланган сан. Һәм шушы кешеләр кулында атом реакторлары. Шулай ук бу шәһәрдә һәр биш кешенең берсе — наркоман, алар да атом объектларында эшли. Шәһәрдә рак белән авыручылар өлкәнең башка урыннары белән чагыштырганда ике тапкыр күбрәк. Һәм шушы авыру, тиле һәм наркоманнар кулына, шушында саклау һәм эшкәртү өчен, дөньяның бөтен почмакларыннан атом калдыкларын китерә башладылар. Бирегә хәзер Япония-

дән, Тайвань, Болгария, Швейцария, Германия, Испания, Венгрия, Көньяк Корея, Чехия, Иран һәм Кытайдан, шулай ук башка илләрдән тагы егерме мең тонна радиоактив калдыклар китерергә җыеналар. Россия хөкүмәте үз җиренә шушы агуны кerтkән өчен бу илләрдән егерме миллиард доллар акча алачак. Бу атом калдыкларын бер генә ил дә үзендә сакларга теләми, безнең җиргә китерә. Без инде барыбыз да үлеп барабыз. Әмма шуның хәтле атом калдыкларын бер урында җыеп саклау дөньяның да башына җитәргә мөмкин. «Маяк»та инде болай да биш йөз мең тонна каты, дүрт йөз миллион кубометр сыек радиоактив калдыклар саклана. Фән теле белән әйткәндә, мин туып үскән Иртәш шәһәрендә бүгенге көндә бер миллиард кюри атом калдыклары бар. Алар күлләрдә, махсус савытларда, җир астында һәм җир өстендә саклана. Һәм бу саклагычлар, бигрәк тә күлләр, инде сиксән процентка шушы агу белән тулган. Аз гына көчле яңгыр яуса яки давыл булса, бу сусаклагычлар ташып агачак, шулай итеп радиоактив калдыклар Төньяк Боз океанына хәтле барып җитәргә мөмкин. Шәһәр астында радиоактив диңгез барлыкка килде, ул, йөзләрчә чакрымнарга сузылган дәрья булып, җир астыннан Чиләбе шәһәренә таба ага. Бу атом калдыклары көньяктан Каспийгача барып җитәргә мөмкин.

Иртәш-Озерский шәһәрендә болай да инде өч йөз данә радиоактив калдыклар каберлеге бар, үле зоналар меңнәрчә чакрымнарга сузылган. «Маяк»та көчле авария булса яки бу якларга табигать бәла-казасы килсә, бер Иртәш яки Караболак кына түгел, бөтен Җир шары юкка чыгарга мөмкин. Чөнки мондагы радиоактив калдыклар шуңа җитә. Болай да меңәрләгән, миллион тонналаган атом калдыклары булган урынга бөтен дөньяның пычрагын китереп тутыру — олы җинаять ул! Бер безгә каршы гына түгел, бөтен кешелеккә каршы җинаять. Шуңа күрә без, Татар Караболагы авылы халкы, һәм мин — Баһадур Фәргать улы, сездән сорыйбыз: Россиягә, «Маяк»ка үзегезнең атом калдыкларыгызны җибәрмәгез. Без инде болай да үлем алдында, әмма без күргәннәр тиздән сезгә дә килергә мөмкин. Без, Уралтау татарлары, Нух пәйгамбәр нәселен дәвам итүче төрки халык, дөньяга мөрәҗәгать итәбез: без, Атлантида кебек, радиация чоңгылына китеп барабыз. Без кисәтәбез: ашыгыч чаралар күрмәсәгез, сезне дә шушы ук хәл көтә, дөньяны атом фаҗигасе көтә. «Маяк» атом берләшмәсе ашыгыч рәвештә ябылырга тиеш, анда бөтен дөньяның атом калдыкларын китерүне туктатырга кирәк. Дөнья җәмәгатьчелеге ашыгыч чаралар күрмәсә, Уралтау артында ахырзаман — апокалипсис башланырга мөмкин.

Баһадур һәр кич менә шушы хәбәрне интернет челтәре аша бөтен дөньяга таратты. Әмма аңа артык иркенәергә ирек бирмәделәр, атна-ун көн дигәндә, паспорт-визалар тикшерәбез дигән булып, авылга район үзәгеннән милиция килеп җитте. Алар бәйләнергә сәбәп тә таптылар, имеш, японнарның рөхсәте Чиләбе шәһәре өчен генә булган, ә Караболакка керәселәре күрсәтелмәгән икән, шуңа күрә алар тиз арада авылдан чыгып китәргә тиешләр. Бу хәбәр японнарның да, Баһадурның да башына күсәк белән китереп суккан кебек булды. Аларның әле бергәләп эшлисе эшләре, сөйләшәсе сүзләре, кыласы гамәлләре бетмәгән иде. Алар шуны да аңлады — болар барысы да Баһадурның интернеттан җибәргән мөрәҗәгатьләренә җавап иде. Органнар шуны ачыкладылар: Иртәштә «Маяк»ка каршы бу малайның ата-анасы бөтен шәһәрне күтәрсә, монда уллары бөтен дөньяны бутап ята. Эшләр артык тирәнгә киткән, дәүләт сере итеп сакланган атом объектына каршы артык зур гаепләүләр тагылган иде. Һәм органнар ашыгыч чаралар күрергә булдылар. Юк, бу чаралар атом куркынычын киметүгә каршы юнәлтелмәгән иде, бу чаралар шул хакта дөньяга хәбәр бирүчеләргә каршы юнәлтелгән иде. Атом-төш коралы белән бәйле нәрсәләр әле һаман Россиянең дәүләт сере булып кала иде.

Икенче көнне Караболак кайнап торды.

Авылга районнан, Чиләбедән хакимият кешеләре, журналистлар, тагы әллә кемнәр килеп тулды. «Маяк»тан, хәтта Мәскәүдән дә зур кешеләр бар икән, диделәр. Кинокамера, фотоаппаратлар күтәреп, кем очрый, шуны сурәткә төшереп йөрүчеләрнең хисабы юк иде. Өйләдән соң, бернигә карамыйча, беркемгә калмастан, бөтен халыкны клубка җыярга куштылар. Имеш, Караболакның алга таба язмышы хәл ителә икән. Башка урынга күчерергә дә мөмкиннәр, ди... Шуңа күрә районнан да, Чиләбедән дә зур кешеләр килгән икән. Бу хәбәрләрдән авыл кырмыска оясы кебек мыжгыды, кешеләрнең эченә шом төште — ничек инде ул яшәп яткан җиреңнән шулай тиз генә башка җиргә күчеп китәсең? Кая китәсең? Барысының да балалары читтә, шәһәрләрдә, биредә аяксыз-кулсыз карт-коры гына ята. Ничек итеп алар бу эшне ерып чыга алсын?

Авылда шундый көтелмәгән ыгы-зыгы башлангач, Караболак халкының киңәше белән, Таһирҗан карт тиз генә Иртәшкә, Гөлҗиһанга шалтыратты. Бәхетенә, Гөлҗиһан өйдә иде, Фәргатьне карарга кайткан булган. Ә Фәргать теге судтан соң авырып киткән, больницага ук салмасалар да, Гөлҗиһан ике арада йөреп, үзе карап тора икән. Авылдагы хәлләрне әйткәч, Гөлҗиһан борчуга төште — бөтен түрәләрнең кубарылып Караболакка килүләре юкка түгел иде. Ул, һич-

шиксез, анда булырга тиеш, әмма Фәргатьнең авырып китүе, җыелышның инде бүген өйләдән соң булырга тиешлеге аны ике кулсыз итте. Шул ук вакытта Чиләбе архивыннан алган белешмәләр бары тик аларда гына, аны соңыннан беркемгә дә бирмәгәннәр. Авыл халкы үз-үзен яклый алырмы, яшьләр бит атна уртасында барысы да шәһәрдә, авылда авыру карт-коры гына. Димәк, нәрсә генә булса да, Гөлҗиһан бүген Караболакка кайтырга тиеш.

Фәргать тә аңа шул тәкъдимне әйтте. Ул хәтта үзе дә кайтырга теләде, әмма ул йөрерлек хәлдә түгел иде. Аяклары гөбе булып шеште, кан анализлары тагы начарланды, ул Гөлҗиһан биргән дарулар белән урын өстендә генә ята ала иде. Фәргать янында Таифәттәйне калдырырга булдылар, Гөлҗиһан исә такси белән булса да Караболакка кайтып килергә булды. Дөрес, бу кыйммәтрәккә төшәргә мөмкин, әмма көнендә Караболактагы җыелышка өлгерергә дә, кичкә яңадан Иртәшкә кайтып җитәргә дә тулы ышаныч бар. Шулай хәл иттеләр. Гөлҗиһан бу хакта шалтыратып Таһирҗан бабайга әйтте һәм юлга кузгалды. Караболакның язмышы хәл ителгәндә, ул читтә кала алмый иде.

## Уникенче бүлек

Ул көнне бөтен Караболак кубарылып урамга чыккан иде. Аяклысы-аяксызы, сукыры-күзлесе, кем, таякка таянып, кем, кешегә ияреп, клубка таба агылдылар. Теге елларда күрше авылларны ничек итеп күчергәннәрен хәтерләүчеләр бар иде, алар шул хакта сөйләп, кешеләрнең күңелләренә шом салдылар. Илле җиде-илле сигезенче елларда Галикәй, Бирдәнеш авыллары халкын, ат абзарларына куып кертеп, шәпшәрә чишендереп, шланглардан хлорлы салкын су белән сиптереп юып, бер сәгать эчендә машиналарга төяп башка җиргә илтеп ташлаганнар иде. Аларның күбесе шунда ачык кырда, фанер өйләрдә ачтан, авырудан үлеп бетте. Алардан калган бөтен әйберләрне, йорт-җирләрне ут төртеп яндырганнар иде, мал-туарны атып, чокырларга күмделәр. Бер яктан, Караболак халкы ул елларда менә шундый фаҗигадән сакланып калды, икенче яктан, алар барыбер өйләрендә кырылып бетә яздылар. Менә хәзер, ул заманнардан соң кырык ел үткәч, аларны тагы кузгатырга булганнар. Халыкның күпчелеге инде моңа риза түгел, аларга үләр һәм күмелер өчен Караболак кирәк иде. Бары тик туган туфрак кирәк иде.

Өлкәдән һәм районнан килгән түрәләр түргә, сәхнәгә менеп кунакладылар. Араларында Мәскәүдән, «Маяк»тан килүчеләр дә бар, диделәр. Килүчеләрнең барысы да диярлек

урыслар иде... Урысча аңламаган, ишетмәгән, күрмәгән карткоры аста аптырап утырды. Япон галимнәре белән бергә Баһадур да клубка килде, чөнки мондый вакытта читтә калырга ярамый иде. Алгы рәткә укытучылар, клубта эшләүчеләр, кайткан кешеләр утырды. Мәскәү һәм Чиләбе журналистлары чабулап аларны төшереп йөри башладылар.

Түрдәге түрәләр беренче сүздән үк мәсьәләне кабыргасы белән куйдылар. Аларның төп максаты — соңгы вакытта «Маяк», Караболак турында дөньяга таралган сүзләрне туктату, аларның ялган икәнлеген исбат итү иде. Шуңа күрә Мәскүдән телевидение чакырылды, «Маяк» вәкилләре җыелып килде, Чиләбе түрәләре аякка басты. Чөнки соңгы вакытта Караболактан интернетка җибәргән хәбәрләр аркасында, чит ил клиентларында күп сораулар туган, бу исә кайбер заказларның өзелүенә китерде. Ә болар барысы да миллион һәм миллиард долларлар белән бәйләнгән. Димәк, «Маяк» турындагы коткыны тамырыннан туктатырга, Караболакның гадәти тормыш белән яшәп ятуын бөтен дөньяга күрсәтергә кирәк иде. Югыйсә монда хәзер ахырзаман белән куркытучы фанатиклар, тиле бәндәләр күренә башлады, берьюлы аларны да үз урыннарына куеп булачак. Бу хәбәрләрне интернет аша дөньяга таратып ятучының гап-гади шизофреник, психик яктан авыру кеше икәнлеген камералар алдында исбатларга кирәк иде. Алар Караболакка менә шундый максат белән килгәннәр иде.

— Перестройка башланганнан бирле, кайбер елгыр бәндәләр, үз мәнфәгатьләрен күздә тотып, «Маяк», радиация темасын куерта башладылар, — дип башлап китте Чиләбедән килгән зур түрә. — Шулай итеп алар дөнья җәмәгатьчелеген дә, тыныч кына яшәп яткан өлкә, авыл халкын да зур хафага салалар, ахырзаман белән куркыталар, дөнья бетү турында кисәтәләр. Имеш, Иртәштәге «Маяк» берләшмәсе дөньяны шундый хәлгә калдырырга мөмкин икән. Болар барысы да чеп-чи ялган, иптәшләр. «Маяк» Россиядә генә түгел, бөтен дөньяда экологик яктан иң куркынычсыз объект санала, моның шулай икәнлеген чит ил галимнәре дә таный, югыйсә алар безнең белән эш йөртмәсләр иде, яңа заказларга килешүләр төземәсләр иде.

Зур түрә шушы кереш сүздән соң канәгать төстә маңгаендагы тирне сөртеп куйды. Аның авызы кипкән иде, өстәлдәге суны алып эчәсе килде, әмма туктап калды. Караболак авылында бернәрсә ашамаска, эчмәскә дип, аларны астан гына кисәтеп җибәргәннәр иде. Шуңа күрә ул, кипкән иреннәрен ялап, сүзен дәвам итте:

— Инде сезнең авыл турында дөньяга таратып яткан ялганнарга да чик куяр вакыт җитте, иптәшләр, — диде ул, шым

гына утырган залга карап. — Кемдер менә ничә еллар инде таратып ята, имеш, илле җиденче елгы аварияән Татар Караболагы да зыян күргән, аны башка урынга күчерергә булганнар икән, дип. Имеш, моның өчен акча да бүлеп бирелгән булган, имеш, ул акчаларны Чиләбедә тотып бетергәннәр дә, Мәскәүгә Татар Караболагы күчерелде, дип хисап биргәннәр. Соңгы вакытта матбугат менә шундый ялган белән тулды. Әйе, ялган, иптәшләр, чөнки безнең кулыбызда Татар Караболагы авылы радиациядән зарар күргән, аны күчерергә кирәк дигән документ юк. Дөрес, галимнәр, белгечләр ул вакытта авылны тикшергәннәр, күчергән очракта, күпмегә төшәсен дә исәпләп чыгарганнар. Әмма озак киңәшкәннән соң, авылга кагылмаска булганнар, күчерергә дигән карар кирәк дип табылмаган. Чөнки радиация болытының авылны читләтеп үтүе ачыкланган. Әгәр сез, чыннан да, ул вакытта радиация астында калган булсагыз, биредә инде беркем утырмас иде. Ә биредә әнә йөз яшьлек кешеләр яши икән. Әйтергә кирәк, иң озын гомерле кешеләр яшәү буенча Татар Караболагы авылы өлкәдә беренче урында тора! Россиянең иң карт кешесе — йөз ундүрт яшьлек татар карчыгы да — Иртәштә яши бит, «Маяк»ның борын төбендә! Нинди радиация, нинди заман ахыры турында сүз булырга мөмкин монда?!

Аның тагы авызы кипте, теле чак әйләнә башлады. Ул бер каршындагы суга, бер залда кәкрәешеп утырган карт-карчыкка, гарип-горабага карады. Юк, аның мондый хәлдә каласы килми иде. Ул үзе белән су алып килмәгәненә үкенеп куйды, әмма өстәлдәге Караболак суына кагылмады.

— Шул имеш-мимешләргә таянып, менә инде ничә еллар Караболак тирәсендә сүз боткасы куерталар, — дип дәвам итте Чиләбе түрәсе, авыр итеп тын алып. — Имеш, Караболак халкына Чернобыльдәге кебек закон кирәк, акча кирәк, ярдәм кирәк. Имеш, аны башка җиргә күчерергә кирәк. Әмма күчерү өчен дә бит әле нигез кирәк, иптәшләр, гөрләп яшәп яткан авылны хәзер ничек кузгатасың? Әнә Мөслим халкы да шулай закон таләп итеп кычкырып йөрде. Хәзер законнары да бар, әмма күчмиләр авылларыннан, шунда ябышып яталар барыбер. Без алар өчен Коншакта биш катлы таш йорт та салдырып карадык, ә алар аннан кире Мөслимгә кайтып киттеләр. Хәзер Караболакта шушы мәсьәләне куертучылар бар, имеш, аны да башка урынга күчерергә кирәк. Әлбәттә, моны халык әйтми, берничә кеше читтән кайтып котыртып йөри. Инде бу сүз Мәскәү, дөнья матбугатына хәтле барып җиткән икән, әйдәгез, алайса, ачыклык кертик — сез башка урынга күчәргә телисезме соң? Әлбәттә, без бу мәсьәлә буенча җирле референдум да уздыра алыр идек, әмма моның нигезе юк, чөнки Караболакның радиациядән зарар

күрүе расланмаган бит. Ә халык фикерен болай гына да белешеп була, шулай бит, иптәшләр?

Астагы халык аптырап калды.

Ничек инде ул, шулай тот та күченү турында эшне кара. Монда бит әле хәзергә сүз күченү турында бармый, авыл халкына ярдәм турында барырга тиеш иде. Халыкның радиациядән зарар күрүен раслап, бөтенләй үлеп беткәнче, ярдәм итеп калырга кирәк иде. Нишләп бу симез урыс һаман бөтен сүзне күчерүгә китереп тери соң? Ул бит болай гына хәл ителә торган нәрсә түгел, моңа ил-авыл белән җыелып, кат-кат киңәшергә кирәк. Үләргә яткан бу карт-коры, гарипдиваналар хәл итәргә тиеш түгел бит мондый нәрсәне. Күчә калсалар, мондагы йорт-җир нишләр, мал-туарлары, бакча-куралары ни хәлдә калыр? Шәһәрдәге балалары, оныклары нәрсә әйтер, туган җирдә төп йорт, нигез калмаса, алар кая кайтып йөрер? Авылның үзе белән нәрсә булыр, Татар Караболагын да, Урыс Караболагы кебек, сөреп, сукалап ташламаслармы? Зиратлар белән нәрсә булыр? Чит җирләрдә үлгәч, аларны кая кайтарып күмәрләр?

Шуны гына көткәндәй, сәхнәдәге агач мөнбәргә «үз татарымыз» — Коншак район җитәкчесе чәчрәп чыкты. Урыс-татар сүзләрен бергә бутап, ул Караболак халкы өстенә ябырылды:

— Караболак исеме белән, сезнең исем белән кемдер сәясәт ясарга маташа, — диде ул, әлсерәшеп утырган карт-карчыкларга карап. — Югыйсә район да, область та сезне беркайчан да ташламады. «Маяк» шартлаганнан соң алынган җирләр сезгә кире бирелде, күпме кирәк, шуның хәтле мал асрыйсыз, итен-маен үзегез теләгән бәягә сатасыз. Авылда фельдшер бар, пенсияләрегез килә, мәктәп, мәчет эшләп тора, менә дигән клубыгыз бар — тагы ни кирәк авыл халкына? Ә кемнәрдер һаман яза, юк нәрсәне һаман куерта, һаман котырта. Чернобыльчеләр белән тигезләүне сорыйлар. Ә Чернобыльнең нинди икәнен беләсезме соң сез, иптәшләр? Җәһәннәм бит анда, кеше яшәрлек җир түгел. Ә сез монда җәннәт җирләрендә яшисез. Инде бу күчү-күчмәү мәсьәләсе шулай кабыргасы белән куелган икән, әйдәгез алайса, бөтен ил алдында, Мәскәү журналистлары алдында үзегез әйтегез — Караболактан күчәргә телисезме сез, юкмы? Менә кулларыгызны күтәреп, үзегез хәл итегез.

Астагы халык бер сүз дәшмәде...

Беркем кулын күтәрмәде, тавыш бирүгә катнашмады. Барысы да кинәт булган бу эштән шомланып, бугаздан алган бу сораудан шашып калган иде. Мәскәү, Чиләбедән килгән телевизорчылар, зыр-зыр әйләнеп, миңгерәеп калган халыкны төшерүләрен дәвам иттеләр.

— Менә бит, халык үзе беркая күчәргә теләми, — дип, «уен»ны дәвам итте Чиләбедән килгән зур түрә. — Чөнки монда яшәү өчен бөтен шартлар тудырылган. Сезгә сер итеп әйтәм, өлкәдәге урыс авыллары күптән җимерелеп бетте инде, ә татар авыллары гөрләтеп яшәп ята. Тирә-юньдә сездән бай халык юк. Шуңа күрә беркемнең мондый авылдан башка җиргә күчәсе килми һәм дөрес эшлиләр.

Аста утырган Караболак халкының башыннан төрле борчулы, хәвефле уйлар сызылып үтте. Алар мондый сөйләшүгә әзер түгелләр иде. Алар үзләреннән нәрсә таләп иткәннәрен дә аңламыйлар иде. Күпләр үзләренә нәрсә кирәген дә белмиләр иде. Шул чакта алга йөгереп Рәшидә чыкты, җәйге эссе булуга карамастан, аның өстендә кара плюш жакет, башында яшел шәл иде.

— Мин авылдан беркая да китмим, — дип үкереп елый башлады ул, өстә тезелешеп утырган таза урысларга карап. — Минем Караболак зиратында матур өем бар, мин шунда китәм. Тик мин үлә алмыйча ятам. Сез дару алып килмәдегезме? Монда бөтен кеше үлә алмыйча ята, чөнки дарулары юк.

Телевизорчылар ашыга-ашыга бу дивана хатынны төшерә башладылар. Аның янына авылның башка тиленләре дә җыелды, аларның кайсы елый, кайсы көлә, барысы да нык ярсыган иде. Инде беркем беркемне тыңламый, һәркем үзенекен сөйли, үзенекен исбатларга тырыша. Клуб эче шау-шу, ыгы-зыгы белән тулды. Бу хәлдән өстәгеләр дә югалып калдылар, алар өчен Мәскәү көткән очрашу килеп чыкмады.

Шул чакта клубка, йөгереп диярлек, Гөлҗиһан килеп керде. Аның ике бите ут булып яна, артка чөеп бәйләгән ак яулыгы астыннан ак чәчләре җилфердәп тора иде. Ул атылып диярлек түргә узды, авыл халкының каршына килеп басты. Аны күргәч, Караболак халкы шунда ук тынып, тынычланып калды, чөнки бу килгән түрәләргә бары тик Гөлҗиһан гына тиешенчә җавап бирә ала иде. Гөлҗиһан үзен дә, Караболак халкын да алдарга юл куймаячак иде.

Аны күргәч, өстәгеләр дә куырылып килделәр...

Бу хатынның язган хатлары, мөрәҗәгатьләре, жалобалары белән аларның өстәл өсләре тулган иде. Ул Чиләбегә генә түгел, Мәскәүгә дә бертуктамый язып тора, президентларны борчый, атомчыларга каршы суд эшләре кузгата, Караболакта гына түгел, Иртәштә дә бөтенесен бутап ята. Ул башта Россия Президенты Б.Ельцинга табак-табак хатлар язды, аннан мондагы хәлләрне В.Путинга аңлата башлады, Россия Дәүләт Думасы, Федерация Советы, Россия Прокуроры, депутатлар, партияләр — берсе дә калмады. Ә алар аның барлык хатларын Чиләбегә җибәреп бардылар. Ә Чиләбе ничек җавап бирәсен белә иде. Моны аңлагач, бу татар

хатыны чит илләргә, халыкара оешмаларга яза башлады, ярдәмгә улы килде, алар бергәләшеп бөтен дөньяны сасыттылар. Хәзер ничек тә аларның кем икәнлеген Мәскәү алдында фаш итәргә кирәк иде, үзләрен юләр, шизофреник итеп калдырырга.

Гөлҗиһан залга күз йөртеп чыкты. Аның каршында авылдашлары тезелешеп утыра. Авырулар, гариплэр, араларында Рәшидә кебек тере диваналар да бар. Арткы рәттә улы Баһадур да утыра, ул агарып, тартылып киткән, күзләрендә эчке әрнү, аңламау. Таһирҗан бабай да, хәтта моңарчы бер җиргә йөрмәгән әнисе дә монда. Барысын да җыйганнар, димәк, җитди сүзләре бар түрәләрнең. Әмма аларның Караболак халкына ярдәм итәргә килмәүләрен Гөлҗиһан тиз аңлап алды, түрдә аның бөтен хатларына кире җавап биреп утырган Чиләбе түрәләре киерелеп утыра иде. Гөлҗиһан аларның ишек төпләрендә күп утырды, аларга Караболак халкының хәлен ничә еллар буе аңлатырга тырышты. Алар аңламадылар да, аңларга да теләмәделәр. Хәзер дә өстән төшерү өчен генә килгәннәре күренеп тора.

— Мин шушы авылда туып үскән Гөлҗиһан Нәбиулла кызы Ханова-Зөлкарнәева булам, — дип башлап китте ул, түрдәгеләргә яны беләнрәк басып. — Хәзер Иртәш шәһәрендә медсестра булып эшлим, авыру иремне калдырып, такси алып кына кайттым. Миңа сүз бирәсезме, авылдашлар?

Клуб эче шау итеп алды, халык кул чаба башлады. Чөнки Гөлҗиһан аларның яклаучысы да, ярдәмчесе дә, адвокатлары да иде. Халыкның аңа ни дәрәҗәдә хөрмәтен күреп, түрдәгеләр дә Гөлҗиһанга сүз бирми кала алмадылар. Һәрхәлдә, бу аларның планнарында булмаса да. Шушындыйлар кайтып җитмәсен дип, алар җыен буласын авылга алдан хәбәр дә итмәгәннәр иде. Ә барыбер иң куркынычы кайтып җиткән. Хәзер көрәшкә әзер булып торырга кирәк инде.

— Сезгә, бәлки, бүген биредә Караболак радиациядән зарар күрмәгән, шуңа күрә аны күчерү кирәк булмаган, дип әйткәннәрдер, — диде ул, авылдашларына туп-туры карап. — Бу хакта бернинди документлар да юк дигәннәрдер. Бар андый документ, менә ул — Караболакның радиациядән зарар күрүе һәм күчерелергә тиешлеге турында карар...

Гөлҗиһанның кулындагы кәгазьне күргәч, халык аһ итте. Кайдадыр андый документ барлыгы турында сөйләсәләр дә, аны әле беркемнең эзләп таба алганы юк иде. Гөлҗиһан бүген аларның каршында шул архив белешмәсен тотып басып тора иде.

— Бу карар 1959 елда ук Чиләбе облисполкомында кабул ителгән, — дип дәвам итте Гөлҗиһан. — Анда Татар Караболагы авылы радиациядән көчле зарар күрүе әйтел-

гән һәм аны башка урынга күчерергә карар кылынган. Без ул вакытта ук Тахталым белән Әширгә күчереләсе булганбыз. Моның өчен хәтта ул замандагы акча белән җитмеш сигез миллион ярым акча да бирелергә тиеш булган. Бирелгәнме ул акчалар, юкмы — без хәзергә белмибез. Ә Мәскәүгә Татар Караболагы күчерелде дигән рапорт киткән. Безне исә шушы радиация арасында үләргә калдырганнар. Дөреслек кырык елдан соң булса да ачылды, әмма авыл халкының күпчелеге инде үлеп бетте. Заманында дүрт мең кешелек зур авылдан җиде йөз кеше яшәп калды. Мин Чиләбе больницасыннан Татар Караболагы авылы кешеләренең авыру тарихларын соратып алдым, анда тикшерелгән мең ике йөз кеше рактан һәм нурланыштан үлгән булган. Ә бөтенесенә «гомуми авыру» диделәр, халыкка кырык ел буе бернинди ярдәм күрсәтмәделәр. Менә бу залда утыручыларның барысы да каннарында атом тамгасы йөртә, аларда нурланыш һәм рак авыруы. Мин моны белеп, медик буларак сөйлим. Хөкүмәт, белә торып, безне радиациядән агуланган урында череп үләргә калдырды. Хөкүмәт, белә торып, безне, бөтен авыл халкын һәм мәктәп балаларын, күчерелгән күрше авылларда атом пычрагын җыярга мәҗбүр итте. Хөкүмәт, белә торып, безнең өстебездә атом тәҗрибәсе уздырды, безне авыру, гарип калдырды. Моның өчен кем җавап бирергә тиеш? Моның өчен дәүләт җавап бирергә тиеш. Моның өчен атомчылар җавап бирергә тиеш. Алар үзләре шушы хәлгә калдырган кешеләргә ярдәм итәргә тиешләр.

— Ә нинди ярдәмне күздә тотасыз соң сез? — дип, тизрәк аны бүлдерергә ашыкты Чиләбе түрәсе. — Авыл халкы башка җиргә күчәргә теләми, пенсиясен ала, бакчасын, малтуарын тота. Татарлар бит алар кеше кулына карап ята торган халык түгел, эшләп ашыйлар...

— Әйе, татарлар беркайчан да кеше кулына карап ятмаганнар, әмма бүген алар арасында да хөкүмәтнең ярдәменә мохтаҗ кешеләр күп, — дип дәвам итте Гөлҗиһан, Чиләбе түрәсенең хәйләсенә капмаска тырышып. — Алар — «Маяк»ның, атомчыларның җинаятьчел эшләре аркасында гарип калган кешеләр, авырулар, диваналар, урын өстендә ятучылар. Карагыз бу залга: биредә күпчелек ярдәмгә мохтаҗ кешеләр утыра. Алар җир җимертеп эшли алмыйлар, ә сез әйткән пенсия бер кап даруга да җитми. Алар барысы да бушка дәваланырга тиеш, әмма моның өчен Караболак халкының радиациядән зарар күрүен танырга кирәк. Судлар юлы белән түгел, закон юлы белән. Биредә утырган бөтен кешенең, бөтен Караболак халкының бернинди судсыз чернобыльче статусына ия булырга хакы бар. Моның артыннан без түгел, сез үзегез йөрергә тиеш, җитәкче әфәнделәр. Чөн-

ки бу сез кылган, сез яшергән җинаять. Ә инде авылны күчерү-күчермәү мәсьәләсенә килгәндә, бу хакта моннан кырык ел элек уйларга кирәк иде. Хәзер моны халык үзе хәл итәргә тиеш. Ә хөкүмәт аларга бу эштә акчалата, ярдәм итәргә тиеш. Теләге булган кеше бу акчага, шәһәрдән барып, квартира сатып алыр, башка җиргә күчәр, теләге булмаганы монда калыр, бу акчага үз-үзен карар. Үзе ничек тели, шулай хәл итәр, шулай бит, авылдашлар?

Авыл халкы аңа гөрләп җавап бирде.

Гөлҗиһан Караболак халкына ни кирәген бик гади рәвештә, бер-ике җөмлә белән әйтте дә бирде. Әйе, дәүләт аларның барысын да радиациядән зарар күргән дип танырга тиеш һәм чернобыльчеләргә биргән ташлама-льготаларны аларга да бирергә тиеш. Дәүләт шулай ук Караболак халкына күчү өчен зур күләмдә акчалата ярдәм итәргә тиеш, әмма теләгән кеше китә, теләмәгәне монда кала, бу акчаларга үзен карый ала. Әлбәттә, бу акчалар гына аларның югалган сәламәтлекләрен кире кайтармас, әмма алар теләсә кая барып дәвалана алачаклар, авылда үлем көтеп ятмаслар.

Бер караганда, кырык ел чишелеш тапмаган бу мәсьәләне, теләгәндә, тиз һәм гади хәл итәргә була кебек. Әмма... Россия бит бу! Монда барысы да кешегә каршы корылган, кешене бәхетсез итү өчен уйланылган. Монда һәр дөрес фикергә каршы ялган бар, мәкер уйлап куелган. Түрәләр, мәсьәләне хәл итәргә теләмәсәләр яки хәл итә алмасалар, демагогиягә, сүз уйнатуга кереп китәләр, халыкны янап, куркытып алырга да күп сорамыйлар. Әмма алар бу татар хатыны белән нишләргә дә белмәделәр. Аны бернәрсә белән дә алдырып булмый иде — ялган белән дә, ялагайлык белән дә, куркыту белән дә. Ул, танк кебек, бөтен ялганны җимереп бара. Аның дәлилләре гади һәм саллы, беркем кире борырлык түгел. Әмма бөтен Мәскәү алдында, телевизион камералар каршында аның сүзен өстә калдырып та булмый. Аны, киресенчә, чыгырыннан чыгарырга, тиле итеп күрсәтергә кирәк иде, ә алар аңа акыллы яктан ачылырга ирек бирделәр. Хәзер бу ялгышны төзәтергә кирәк, әмма ничек итеп? Алар аптырашып бер-берләренә караштылар. Шулчак «Маяк» вәкиле сүз алды:

— Без сезне Иртәштә яхшы беләбез, Гөлҗиһан ханым, — дип башлап китте ул, үзенең сүзен проблемадан шәхескә күчереп. — Сез шәһәрнең иң яхшы больницасында яхшы акчалы эштә эшлисез, әнә бирегә такси белән генә кайткансыз. Шәһәр сезнең гаиләгә иң яхшы квартирасын бирде. Ялгышмасам, өч бүлмәле бугай. Ирегез престижный урында юрист булып эшли, адвокат. Шәһәр сезнең балаларыгызны укытты, кеше итте. Ә шәһәр ул — «Маяк» дигән сүз. Мин шуны

гына аңламыйм, ни үчегез бар сезнең «Маяк»та, үзегезне кеше иткән, куенына сыендырган шәһәрдә? Ник сез аның турында бөтен дөньяга пычрак таратасыз, яла ягасыз, юк итәргә йөрисез? Анда барып чыкмагач, бирегә кайтып, авыл халкын котыртасыз, аларга тыныч кына яшәргә ирек бирмисез. Менә шушы халык алдында, ачыктан-ачык әйтегез әле: нәрсә кирәк сезгә? Ник дөньяны болгатасыз сез?

Гөлҗиһан бу бәндәнең кайсы якка борганын шунда ук аңлап алды.

Ул Гөлҗиһанны чыгырыннан чыгарырга, талашка, ызгышка өстерәп кертергә тели иде. Ул сөйләшүне Караболак турында түгел, Гөлҗиһанның үзе турында куертырга тели. Әмма Гөлҗиһан бу көрәш юлында мондый кешеләрне инде күп күрде, шуңа күрә кабынып та китмәде, бәхәскә дә кереп тормады.

— Миңа дөреслек кирәк, — диде ул, корыч тавыш белән. — Әтиемнең, туганнарымның, авылдашларымның ни өчен шулай газапланып үлүләрен белергә кирәк. Иремнең ни өчен егерме биш яшьтән дөм сукыр калуын, балаларымның ни өчен телсез-чукрак булып тууын белергә кирәк. Мең еллык туган авылымның нигә болай череп үлүен белергә кирәк. Һәм мин моны белермен дә, Алла теләсә. Һәм тиешле кешеләр бу җинаятьләре өчен барыбер җавап бирәчәкләр. Шул исәптән сез дә. Сез монда, камералар күтәреп, халыкны алдарга, башын миңгерәйтергә килгәнсез. Боларның бер сүзенә дә ышанмагыз, авылдашлар, ашыгып бернинди карар да кабул итмәгез. Болар сезгә ярдәм итә торган кешеләр түгел.

Гөлҗиһан шулай диде дә, халыктан гафу үтенеп, чыгарга таба атлады. Чөнки аны Иртәштә авыру ире көтеп ята иде. Урамда килгән таксие көтеп тора. Ул халыкка әйтәсе сүзен әйтте, аңлатасын аңлатты, хәзер шушыларны башка урында исбатларга кирәк. Мәскәүдә булмый икән, чит илләрдә, әмма барыбер дөреслекне табарга, Караболак халкына ярдәм итәргә кирәк.

Шулчак аның янына йөгереп Рәшидә килде.

— Мин Караболактан беркая да китмим, чөнки минем зиратта матур өем бар, — диде ул, Гөлҗиһанга сыенып. — Син дә китмә, яме, без бергә торырбыз.

— Юк, юк, Рәшидә, мин бер җиргә дә китмим, — диде Гөлҗиһан, күз яшьләрен чак тыеп.

— Тик мин үлә алмыйча ятам. Син миңа берәр төймә алып кайтмадыңмы?

Гөлҗиһан, тиз генә кесәсеннән чыгарып, Рәшидәгә үзенең даруларын бирде. Рәшидә аларны берәм-берәм залдагы халыкка тарата башлады.

Гөлҗиһан чыгып китте, җыелыш дәвам итеп калды.

Әнисе артыннан тизрәк Баһадур да ияреп чыкты. Ана белән ул кочаклашып күрештеләр. Баһадурның әнисен озак-озак кочаклап торасы, бер дә үз яныннан җибәрәсе килмәде. Аның әнисе алдында тезләнеп, аякларын үбеп, рәхмәт әйтәсе килде. Барысы өчен дә — дөньяда булганы өчен дә, нәкъ шундый булганы өчен дә. Алар шактый озак бер-берләренә сыенып, сүзсез басып тордылар, бер-берләрен сүзсез дә аңладылар.

Ана белән бала бу дөньяда соңгы тапкыр очрашалар иде…

Караболак бу очрашуның соңгы шаһиты булды…

Баһадур яңадан клубка кергәндә, авыл халкы ярсып урыныннан купкан, һәркем үзенекен сөйләп калырга тырыша иде. Караболак халкы Чиләбе җитәкчеләренең ни өчен бирегә килгәннәрен аңлап алган һәм, хәзер аларның йөзләренә бәреп, дөреслекне әйтеп калырга тырышалар.

— Без монда беркемгә кирәк түгел, безнең биредә үлеп беткәнебезне көтәләр, аннан түрәләр өчен проблема да калмаячак, — дип, туп-турыдан яра укытучы татар хатыны. — Күбебез диагнозыбызны белмичә дә үлә. Минем бөтен нәселем рактан үлеп бетеп бара. Апам Саҗидә рактан үлде, аның ире Сабирҗан рактан үлде, икенче апам Мәүҗидә аяксыз утыра, аның ире Хәкимҗан шушы радиация аркасында күзсез, аяксыз калды. Туганымның улы Марс утыз бер яшьтә тәгәрәп үлде. Бертуган абыем Мөкарәм урын өстендә ятып, тилмереп үлде. Сез монда килеп, рәхәтләнеп, яшисез, дип безне мыскыл итәсез. Без монда барыбыз да үләргә чират баскан. Без хәтта район больницасына да барып күренә алмыйбыз. Рак диагнозы күп вакытта үләр алдыннан гына куела, анда нинди дару ярдәм итсен инде? Юллар юк, транспорт юк, күперләр юк. Авыл башыннан газ торбалары үтә, ә Караболакка кертелмәгән. Ни район, ни Чиләбе безгә берни белән дә ярдәм итми, сайлауга бармаган өчен, Караболак халкыннан шулай үч алалар. Күрше урыс шәһәрләреннән килеп, карткорыны кыйнап, талап китү очраклары да күбәйде, чөнки авылда милиция юк, хокук саклаучылар юк. Дөресен әйткәндә, мең еллар гөрләп торган авылда нәрсәгә тотынсаң, шул юк. Яшьләргә эш юк, инде, балалар аз, дип, мәктәбебезне дә ябарга торалар. Татар балалары, күрше урыс авылына барып, урысча укырга тиеш булачаклар. Безнең тәнебезне генә түгел, җаныбызны да талыйлар. Бу илгә татарлар кирәк түгел. Бу илгә, гомумән, кеше кирәк түгел…

Мәскәү телевидениесенең ашыга-ашыга бу хатынны төшергәнен күреп, Чиләбе түрәләре бирегә ник килгәннәренә үкенә башлаганнар иде инде. Гөлҗиһан боларга ут төртеп, ничек сөйләшергә өйрәтеп киткән иде. Әнә ул арада тимер

аяклы авыл агае сикереп торды, түрәләргә түгел, камерага карап сөйли дә башлады...

— Мин сезнең каршыда чуен аяктан басып торам. Бер аягымны кистеләр, инде икенчесен кисәргә җыеналар. Мин ул елларда үле зонада лесник булып эшләдем. Әмма безгә анда радиация икәнлеген әйтмәделәр, без урмандагы һәр агач өчен җавап бирә идек. Әмма кеше өчен бу илдә беркем җавап бирми булып чыкты. Минем белән ул чакта эшләгән бөтен лесниклар, аяклары череп, үлеп бетте инде. Соңгы көнгә хәтле миңа дөрес диагноз куймадылар, авыруым билгеле булгач, инде соң, берни эшли алмыйбыз, диделәр. Операциядән баш тарттылар. Балалар белән тиенләп акча җыеп, үзебез түләп кистердек аякны. Мин хәзер үземнең «Маяк»тагы шартлау аркасында шушы хәлгә калуымны бик яхшы беләм, әмма хөкүмәттән бернинди ярдәм күргәнем юк. Кем миңа ярдәм итәргә тиеш — әйтегез алайса?

Урманчы картның сүзеннән зал бермәл тынып торды да тагы шаулый башлады. Хәзер халык, мөмкинлектән файдаланып, килгән түрәләрдән җавап таләп итә иде. Тегеләр тиз генә җыелышны түгәрәкләргә дә тырышып карадылар, әмма халык кызган иде инде, беркемне сәхнәдән төшермәде, беркемне залдан чыгармады. Беркем беркемне тыңламады, балалар кычкырып елый, тиләләр тәгәрәп көлә башлады. Боларны тыярга, туктатырга олы кешенең сүзе кирәк иде. Шул чакта Таһирҗан карт халык алдына чыгып басты:

— Сабыр, җәмәгать, — диде ул, авылдашларына карап, татарча.

Халык шым булды, бөтенесе тынып Таһирҗан картка текәлделәр.

Таһирҗан карт сәхнәгә борылып, сүзен урыс телендә дәвам итте:

— Мин сезнең Караболакка килү максатыгызны белмим, — диде ул, һәр сүзен уйлап. — Әмма халык белән бу уенны уйнамаска кирәк иде. Без сезне кырык ел көттек, кырык ел буе хәлебезне аңлатып сезгә яздык, әмма җавап та, ярдәм дә алмадык. Хәзер дә сез Караболакны беркая да күчерергә җыенмыйсыз, үзегез әйткәнчә, моның өчен закон кирәк, Караболакны радиациядән зарар күргән дип тану кирәк. Ә сезгә бу кирәкми. Ә бу кул күтәртеп уйнау соңыннан халыкның үзен гаепләү өчен кирәк — менә алар үзләре күчәргә теләми бит дип әйтү өчен кирәк. Һәм болар барысы да Мәскәү кешеләре, телевидение алдында эшләнә. Шуңа күрә халык сезнең бу уеныгызга катнашмады. Сез Караболакта озын гомерле кешеләр яшәве белән дә уйнап алмакчы булдыгыз. Әйе, элек шулай булган, бу авылда халык йөзгә, хәтта йөз иллегә хәтле яшәгән. Мин үзем Аллаһ ярдәме белән йөзгә

җиттем. Караболак халкының бөтен тормышы, язмышы минем күз алдымда үтте. Без башта халыкның ни сәбәпле болай кырылганын белмәдек, чөнки ул вакытта бөтен нәрсә сер иде. Хәзер без инде барысын да беләбез — Караболак халкының бар газаплары «Маяк» атом комбинаты аркасында икән. Аннан килеп торган агу, радиация халыкны чалгы урынына кыра. Безнең бөтен ашаганыбыз, эчкәнебез, сулаганыбыз шул зәхмәттән тора. Авылда хәзер дә радиация мең тапкыр артык булган урыннар бар, әнә анысын япон галимнәре әйтер, алар көн саен үлчәп тора. Мондый шартларда, әлбәттә, яшәп булмый, исән калып булмый. Безнең тамырларыбыз артык нык булган, артык көчле булган, шуңа күрә һаман үлеп бетмибез. Хәзер инде калган халыкка ничек ярдәм итү турында уйларга кирәк. Дәүләт һәм «Маяк» безнең алда зур гаепле, зур бурычлы. Алар бу гаепләрен йоларга тиешләр, чөнки кешеләрнең бу газаплары өчен әле аларга Аллаһ каршында да җавап бирергә туры киләчәк. Барысын да Гөлҗиһан кызым әйткәнчә эшләргә кирәк — кешеләрне суд юлларында йөртеп газапламыйча гына, закон белән, радиациядән зарар күргәннәрен танырга кирәк. Күчәргә теләгән кешеләрнең акчасын кулларына бирергә, кая барырга, ничек яшәргә кирәген алар үзләре хәл итәр. Калырга теләгән кешеләр монда калыр, әмма аларга да шул ук компенсацияне бирергә. Нәрсә, миллиардлаган доллар эшләгән «Маяк»ның шуңа мөмкинлеге юкмы? Дәүләтнең үз халкына ярдәм итәрлек рәте, теләге юкмы? Шулай икән, халыкка ачыктан-ачык әйтергә кирәк, халык белән алай уйнарга ярамый. Әмма сез бит боларның берсен дә эшләргә теләмисез. Теге елларда күчкән кешеләр дә һаман такта баракларда яшәп интегә, аларны да илтеп ташладыгыз да оныттыгыз. Караболак халкы үзен кырга чыгарып атканга беркайчан да риза булмаячак. Шуңа күрә бу залда беркем кул күтәрмәде. Без күптән инде бу илдән, бу хөкүмәттән мәрхәмәт көтмибез, чөнки монда барысы да адәм баласына каршы эшләнә. Мәскәүләрдән, Чиләбеләрдән бирегә хәтле килеп җиткәнсез икән, шунысын да белеп китегез — бу илнең киләчәге юк. Әмма, кызганычка каршы, татар милләте дә шушы атом казанында янарга мәҗбүр. Үзегез дә кеше кебек яши белмәдегез, безгә дә ирек бирмәдегез. Хәзер нинди күчү турында сүз булырга мөмкин, кешелек башка дөньяга күчәргә торганда? Аллаһтан мәрхәмәт сорарга гына кала, кичерү сорарга...

Картның соңгы сүзләрен аңлап бетермәсәләр дә, ул күпләрне шомландырды, бигрәк тә читтән килгәннәрне. Чөнки йөзгә җиткән бу карт үз-үзен тотышы белән дә, сүзләре, тышкы кыяфәте белән дә барысыннан да аерылып тора иде. Мөгаен, борынгы пәйгамбәрләр, әүлиялар, изгеләр шундый бул-

гандыр. Ул һәр сүзен белеп, ышанып, әллә нинди күңел тирәнлекләреннән алып сөйли. Әйтерсең лә җиһан йөзенә язып калдырылган язмышлар китабын укый. Ул арада халыкның шомлануын тагы да көчәйтеп, ишек төбеннән Рәшидәнең кычкыруы ишетелде:

— Сез барыгыз да үлә алмыйча ятачаксыз әле, минем кебек, — дип, көлә-көлә кычкырды ул, түрдәге түрәләргә карап. — Чөнки монда килгән кеше исән калмый, безнең авыл агулы бит ул. Ә агуны сез җибәреп ятасыз. Менә үзегезгә дә эләкте хәзер.

Аны, көчкә-чакка юатып, клубтан алып чыгып киттеләр.

Түрдәгеләргә бу сөйләшү, мондый очрашу бер дә ошамый иде. Караңгы бер авыл халкы аларны юләргә, җинаятьчегә чыгарды да калдырды. Һәм Мәскәүдән килгән вәкилләр, журналистлар алдында. Соңгы сүзне һич кенә дә алардан әйттерергә ярамый иде, соңгы фикер авыл халкыныкы түгел, атомчыларныкы булырга тиеш. Чөнки бу очрашуның максаты да шул иде бит — соңгы вакытта дөнья матбугатында «Маяк»ка каршы булган гаепләүләрне юкка чыгару, аны оештырып ятучыларны фаш итү. Ә хәзергә бу надан авыл халкы аларның үзләрен фаш итә, үзләрен гаепли. Имеш, аларның бөтен нәсел чирләрендә радиация гаепле икән, «Маяк» гаепле. Димәк, боларны котыртып, өйрәтеп торучылар бар. Шул ук японнар да юкка йөрми бу тирәдә. Эш болай барса, «Маяк» тирәсендә зур гауга кубарга мөмкин. Халыкара гауга. Һәм алга таба җыелыш болай дәвам итә алмый иде. Сүзне тагы «Маяк» вәкиле алды:

— Менә мин гомерем буе сез сүккән «Маяк»та эшләдем, хәтта тууым да шул Иртәштә, — дип башлап китте ул сүзен тыныч кына. — Ә авыру кешегә охшаганмы мин? Юк, әлбәттә. «Маяк»та менә минем кебек нормаль кешеләр эшли, Иртәштә сау-сәламәт кешеләр яши. Сез сөйләгәннәрне тыңласаң, без анда барыбыз да радиациядән үлеп бетәргә тиеш идек инде. Ә ул өлкәдә иң чиста, иң матур шәһәр. «Маяк»ның өстендә утырган шәһәр шундый булгач, аннан кырык чакрымда урнашкан авыл нигә радиациядән чирләргә тиеш инде? Монда әллә нинди сәламәт булмаган психоз — һаман кемнедер гаепләргә тырышу, коткы тарату. Бу наданлыктан килә инде, әлбәттә, ә кемнәрдер шуннан бик оста файдалана. Моның өчен аларга зур акчалар түләнә. Чит илләргә Россиянең куәтле атом державасы булуы кирәк түгел, алар аны коралсызландыру, хәлсезләндерү өчен барысын да эшлиләр. Аның өчен, бер яктан, менә сезнең кебек беркатлы халыкны атомчыларга каршы котырталар, икенче яктан, шәһәр халкын сатып алалар. Радиация турында әкиятне дә шулар тарата. Әйдәгез, җәмәгать, бер-беребезне урынсызга гаепләүне

туктатыйк. Татар авыллары гомер буе «Маяк»ка менә дигән эшче көчләр биреп торды, шәһәр халкын азык-төлек белән тәэмин итте.

— Ә сез аңа каршы нәрсә эшләдегез?! — дип кычкырды урыннан кемдер. — Безне агуга батырдыгыз.

«Маяк» вәкиле аңа җавап биреп өлгермәде, әллә кайдан тагы Рәшидә йөгереп килеп чыкты. Ул, сәхнә алдына ук барып басып, «Маяк» вәкиленә төртеп күрсәтә-күрсәтә, үзенекен сөйли башлады:

— Ә синең башыңда күгәрчен йомыркасы хәтле шеш бар. Син дә минем кебек үлә алмыйча ятачаксың әле. Твоя галава — шишка. Яйца-шишка.

Килгән урыс аңласын дип, ул аның борын төбендә йодрыгын әйләндереп күрсәтә башлады, аннан башына төртеп күрсәтте. Дивана хатынның бу сүзләреннән «Маяк» вәкиле агарып китте, әмма бер сүз дә әйтмәде, тизрәк урынына барып утырды. Соңгы вакытта ул баш авыртуы белән бик интегә, әмма табибка күренергә курка иде. Аның ата-анасы да шушы авырудан китте, бергә эшләүчеләрдән дә баш мие рагы белән үлүчеләр булды. Җитмәсә, бу тиле хатын да әнә шул хакта сөйли. Ул инде бирегә ник килгәненә үкенә башлады, бу мәгънәсез җыелышның тизрәк бетүен көтте. Сөйлисе кеше инде сөйләп бетергән, әйтәсе әйтелгән, инде йомгакларга да була иде. Шулчак ишек төбеннән карт япон галиме күтәрелде, урыс телен вата-җимерә, ул үзенә сүз бирүләрен сорады. Түрдәгеләр аны күрмәмешкә, ишетмәмешкә салындылар, аларга карар кабул итәргә һәм таралырга кирәк иде. Әмма астагы халыкның таралырга исәбе юк, ахры, алар карт японга сүз бирүләрен сорап кычкыра башладылар. Ярсыган, түрдәгеләрнең ялганыннан тәмам туйган халыкны туктатырга мөмкин түгел иде. Шуңа күрә сәхнәдәгеләр бу хәлләргә кул селтәделәр, япон галименә дә сүз бирделәр. Аның урысча интегеп сөйләгәнен белгәнгә, галимне инглизчәдән тәрҗемә итәргә Баһадур да чыгып басты.

— Бу авылда радиациянең бүген дә нормадан бик күпкә артык икәнлеген без инде исбатладык, — дип башлап китте галим үзенең сүзен. — Менә бу приборга карагыз — хәтта бу бинада да ул нормадан утыз-кырык тапкыр артык. Сәхнәдә дә, менә карагыз, шул ук хәл, хәтта артыграк та күрсәтә. Бу урында кирәгеннән артык озак тору нурланышка китерергә мөмкин.

Сәхнәдәгеләр, капкынга эләккән бүре кебек, бу сүзләрдән кая барырга белмәделәр. Менә ничә сәгать инде алар бу авылда барысы да яхшы дип исбатларга тырыштылар, ә бу карт япон приборын тотып чыкты да, радиация нормадан артык, ди. Нурланыш белән яный. Ә чыннан да шулай булса? Бу

авыл халкының инде югалтыр нәрсәсе юк, ә читтән килгәннәр нигә моңа дучар ителергә тиеш. Әмма алар сәхнәне ташлап чыгып та китә алмыйлар, халык алар каршына кыя булып баскан. Түрәләр, чыннан да, үзләре салган тимер капкында калганнар иде.

— Ә инде кешеләр мәсьәләсенә килгәндә, — дип дәвам итте япон галиме, — без авыл халкының күпчелеген тикшердек һәм аларның көчле атом нурланышы алуы билгеле булды. Бу нурланыш хәтта Хиросимадагыга караганда да күбрәк булып чыкты, бу, әлбәттә, коточкыч хәл. Күп кешеләрнең сөякләренә стронций-90 утырганын ачыкладык, ә ул бик куркыныч радиоактив матдә. Ул кеше организмыннан өч йөз ел эчендә генә чыгып бетә, әгәр өстәлеп тормаса. Ә монда радионуклидлар һаман өстәлеп тора, чөнки янәшәдә генә атом объекты эшләвен дәвам итә. Безнең тикшерүләребез буенча, Караболакта бөтен балаларда да генетик яктан зур үзгәрешләр күзәтелә. Дөресрәк итеп әйткәндә, алар барысы да диярлек хромосомалар буенча мутантлар, бу исә турыдан-туры радиация тәэсире нәтиҗәсе. Бу исә, үз чиратында, кырык буынның гарипләнүенә китерә. Без тикшергән барлык балаларда диярлек кан рагы табылды. Бу да көчле радиация тәэсире. Авылда баш мие урынына сулы капчык йөртүчеләр дә бар. Шулай ук сыңар бөер белән туучылар да очрый. Инде алты бармаклы яки бөтенләй бармаксыз балалар турында әйтеп тә тормыйбыз, алар күп. Иң куркынычы — бу кешеләргә һаман радиация өстәлеп тора, алар эчә торган суда, ашый торган ризыкларында, сулый торган һаваларында радионуклидлар нормадан йөз тапкыр күбрәк! Шушы шартларда аларның ничек исән калуларына һәм ничек яшәп ятуларына гаҗәпләнергә генә кала. Кызганыч, без үзебезнең тикшерүләребезне тәмамлый алмадык, безне иртәгә биредән китәргә мәҗбүр итәләр. Без Караболак халкына кулыбыздан килгәнчә ярдәм итәргә тырыштык, чөнки моннан илле ел элек үзебез дә шундый ук атом фаҗигасенә дучар булдык. Әмма безнең дәүләтебез атом фаҗигасе кичергән кешеләргә карата бик игътибарлы, Япониядә барысы да алар өчен көйләнгән, алар тулысынча дәүләт каравында. Әгәр безнең хөкүмәтебез ризалык бирсә, мин Караболакның яшьләрен булса да Япониягә алып китү өчен барысын да эшләячәкмен. Аларга тиешенчә дәваланырга кирәк, алар шулай гына сәламәт нәсел калдыра ала. Чөнки мин, монда ике ел рәттән килеп, шуны аңладым — бу халык җир йөзеннән менә шулай эзсез югалырга тиеш түгел. Мин күрдем: татарлар бик талантлы, тырыш халык, бик-бик борынгы милләт. Әмма аларның фаҗигасе үзләрен җиңгән кавемнең аяк астында яшәүдә. Алар монда бөтенләй юкка чыгачаклар. Мин татарларның Росси-

ягә кирәк түгеллеген аңладым, әмма алар безгә кирәк. Чөнки без уртак фаҗига кичергән халык. Мин дә үземдә илле ел буе атом тамгасы йөртәм. Шуңа күрә бу халыкның хәлен бик яхшы аңлыйм. Мин алар алдында үземнең чал башымны иям…

Карт галимнең күзләренә яшь бәреп чыкты.

Аннан ул үзен тәрҗемә итеп торган Баһадурга таба борылды.

Бу авылда аның өчен иң зур табыш — менә шушы бала иде. Аның өчен генә түгел, бөтен дөнья өчен ачыш, могҗиза иде бу татар баласы. Аның акыл күзәнәкләренә бөтен кешелек тарихы язылган, ул аның башлангычын да, ахырын да белә. Димәк, бу очрашуда да соңгы сүзне ул әйтергә тиеш…

Галим, авырлык белән булса да, урыс теленә күчте:

— Минем янымда басып торган бу бала — дөньяның могҗизасы, — диде ул, Баһадурның иңнәреннән кочып. — Мондый акыл иясе барында, минем сүзләрем көчсез. Шуңа күрә дә бу очрашуда соңгы сүзне ул әйтергә тиеш. Сөйлә, улым.

Баһадурның үзенең дә әйтер сүзләре бар иде, әмма ул олылар алдында яхшысынмады. Әмма ул әйтәсе сүзне берәү дә әйтмәгәнгә күрә, тәвәккәлләргә булды. Кешеләр бу залдан иң кирәген ишетеп китәргә тиешләр иде. Ул төп фикерен килгән кешеләр өчен урыс телендә әйтте, кирәк тапкан урыннарын авылдашлары өчен татарча да аңлатты, урыны-урыны белән инглизчәгә дә күчеп алды. Мәскәүдән килгән телевизионщиклар мондый тере могҗиза алдында телсез калдылар, аның һәр сүзен язып, төшереп барырга тырыштылар.

— Мин Баһадур Зөлкарнәй, Иртәш шәһәрендә туып үстем, миңа унике яшь, — дип башлап китте ул, тып-тын калган халыкка карап. — Минем бөтен гомерем атом бомбасы ясый торган шәһәрдә үтте. Без анда барыбыз да җәһәннәм казаны өстендә утырабыз. Анда бүгенге көндә бер миллиард кюри атом калдыгы саклана, бу бөтен дөньяны бер мизгелдә юк итәргә җитә. Һәм шуның өстенә хәзер унбиш илдән «Маяк»ка атом калдыклары кертергә җыеналар. Чиләбе өлкәсенең Кыштым, Карабаш, Иртәш шәһәрләре дөньяда экологик яктан иң пычранган шәһәрләр санала. Шуңа күрә биредә күп кеше рактан авырый, «Маяк»ның бөтен генераль директорлары рактан үлеп бара. Иртәштә яшәүчеләрнең җитмеш проценты психик яктан тайпылышлы, һәр дүртбиш кешенең берсе — наркоман. Менә шушылар кулында дистәләгән атом реакторы, миллионлаган тонна уран, плутоний, миллиардлаган тонна атом калдыклары. Шушының өстенә берәр табигать бәласе дә булып куйса, Урал таулары күккә очачак. Ә бу якларда метеорит яңгырлары, көчле өер-

мәләр, гарасатлар гел булып тора. Шуңа күрә бүген сүз бары тик «Маяк»ны ябу турында гына булырга мөмкин. Сезнең һаман шуны аңламавыгызга мин бик гаҗәпләнәм. «Маяк» атом берләшмәсе хәзер бер Караболакка гына түгел, бөтен Җир шарына яный, бөтен кешелеккә куркыныч тудырырга мөмкин... Без, Караболак халкы, инде китеп барабыз. Безнең кешелекне бу фаҗига турында кисәтергә хакыбыз бар. Җәннәт кебек бу җирләр, бу саф сулар, күлләр, яшел урманнар, байлык тулы таулар безгә Аллаһтан әманәт итеп бирелгән иде. Без бу җирне, бу нигъмәтне заман ахырына кадәр сакларга тиеш идек. Ә кешеләр нишләде? Бар дөньяны атом чүплегенә әйләндерде, җирне, суны, һаваны һәм үзүзен агулады. Без хәзер барыбыз да атом тамгасы йөртәбез, шул исәптән сез дә, түрдә утыручылар... Кешелек ялгыш юлга кереп китте, һәм ул моның өчен җавап бирәчәк... Теге дөньяда да, монысында да... Әмма җәһәннәм уты атом утына караганда миллионлаган тапкыр көчлерәк булачак. Әле тәүбәгә килергә соң түгел, әле ялгышларны төзәтергә вакыт бар, әмма тиздән барысы да үзгәрәчәк. Таулар тетелеп күккә очканда, күкләр ишелеп җиргә төшкәндә, җир эчендәге бөтен нәрсәне актарып өскә чыгарганда, дәрья сулары бергә җыелып кушылганда — ул көн киләчәк... Һәм барыбыз да, җавап бирү өчен, Аллаһ каршына басачакбыз. Һәм без күчәчәкбез. Бу — бөек күченү булачак... Барыгыз да шул күченүгә әзерләнегез...

Кешеләр, тын да алмыйча, Баһадурны тыңладылар. Әйтерсең лә алар каршында адәм баласы түгел, башка дөньядан килгән изге зат басып тора иде. Әйтерсең лә аның теле белән фәрештәләр сөйли. Аның теле белән пәйгамбәрләр, әүлиялар кисәтә. Аның сүзләренә ышанмыйча мөмкин түгел иде, ә ышангач, ничек яшәргә? Нишләргә? Һәркем бу сорауга үзе җавап табарга, үз гамәлен үзе кылырга тиеш иде.

Җыен бетте.

Халык өйләренә таралды.

Бер карар да кабул ителмәде, чөнки эш карарлардан узган иде инде.

Килгән түрәләрне озатучы булмады.

Бары тик Рәшидә генә алар артыннан авыл башына хәтле йөгереп барды. Ул: «Барыбыз да шунда күчәбез! Барыбыз да шунда күчәбез!» — дип әсәрләнеп, өзгәләнеп кычкыра иде. Бу дивана хатынның хәвефле тавышы аларны бик озак артларыннан куа барды, эзәрлекләде, соңыннан төшләренә кереп газаплады.

«Барыбыз да шунда күчәбез...»

«Барыбыз да шунда күчәбез...»

Әмма алар берсе дә моңа әзер түгел иде...

## Унөченче бүлек

Японнар Караболактан китәргә әзерләнә башладылар.

Аларның Баһадурны һич кенә дә үзләреннән калдырасылары килми иде. Бигрәк тә карт галим нишләргә белмәде, чөнки ул бу татар баласын үз улыдай күреп яраткан иде. Хәер, аның үз гомерендә баласы булмады, чөнки ул Хиросима корбаны иде. Ул үзе дә гомер буе кан күзәнәкләрендә атом тамгасы йөртә, мәңгегә нәселсез булырга дучар ителгән. Шуңа күрә ул бөтен гомерен атом-төш коралын куллануга каршы көрәшкә багышлады, бөтен дөнья буенча йөреп, атом корбаннарына ярдәм фонды оештырды. Караболакка ул инде икенче ел рәттән килә, мондагы халыкның чыдамлыгы аны гаҗәпкә калдырды. Тәннәрендә, каннарында, сөяк-буыннарында шул дәрәҗәдә радионуклидлар йөртеп, ничек исән калырга, яшәргә мөмкин икән? Алар бит яхшы даруның да нәрсә икәнен белмиләр, тиешле дәвалау да күргәннәре юк. Аларны килеп өйрәнгәннәр генә, әмма ярдәм итмәгәннәр. Иң кызганычы — балалар, алар үзләренең ни дәрәҗәдә бәхетсезлеккә дучар булуларын аңламыйлар. Бүген йөгереп йөргән бу нәни аяклары иртәгә шартлап сынасын, бүген якты дөньяны күргән күзләре иртәгә сукыраясын, чәчәк кебек шиңәселәрен, суласыларын белмиләр алар. Бәлки, белмәүләре белән бәхетлеләрдер дә...

Ә Баһадур алай түгел. Ул барысын да белә. Үзендә нинди авыру икәнлеген дә, кайчанрак бу дөньядан китәсен дә, киткәч, нәрсә буласын да — барысын да белә яңа уникесе тулган бу татар малае. Анда әүлиялар акылы бар. Һәм ул дөньяда бик сирәк очрый торган гыйлемгә ия. Дөресрәге, ике дөнья гыйлеменә. Ул бу дөнья цивилизациясен дә яхшы белә, илаһи дөньядан да бик гыйлемле. Бу мәсьәләдә ул карт япон галиме белмәгәннәрне дә белә.

Карт галимнең Баһадурны бик тә үзе белән алып китәсе килә...

Бу балада булган гайре табигый акыл аны сискәндерә дә, галим буларак, бик нык кызыксындыра да. Нәрсә, нәселдән килгән табигый аңмы бу, әллә... Әллә радиациянең шушы рәвешле кеше акылына көчле тәэсир итүеме? Моны әле беркем белми иде, һәм шуңа күрә Баһадурны да лаборатория шартларында яхшылап өйрәнергә кирәк. Ә моны бары тик Япониядә генә эшләп була. Аның үз илендә, Япониядә, хәзер дөньяда тиңе булмаган фән-техника революциясе бара, тиңе булмаган ачышлар ясала. Ә Баһадурның аң-акыл мөмкинлекләре аларны да үтеп китә, карт галимнең мондый могҗизаны әле беркайчан да күргәне булмады. Иң соңгы модельле компьютерлар да бу бала алдын-

да бик тиз көчсез булып калалар. Тик моның хикмәтен беркем аңламый, шуңа күрә карт галим аны үзе белән Япониягә алып китәргә тели.

Алып китәргә теләвенең тагы бер сәбәбе бар — Баһадурга ашыгыч рәвештә ярдәм кирәк. Аның сәламәтлеге яхшы түгел. Баһадур үзенең анализларын бирергә теләмәсә дә, авылга килгән япон галимнәре аны да тикшерделәр һәм канында зур үзгәрешләр таптылар. Баһадурда ак кан күзәнәкләре кимеп килә иде, бу исә кан рагының башлануы дигән сүз. Россиядә моны дәвалау юллары юк, Япониядә дә бу өлкәдә әле тотынып кына киләләр. Әмма анда бу процессны туктатып тора торган дарулар, мөмкинлекләр бар, тик аларны клиник шартларда гына алырга була. Аның өчен озак вакытлар, хәтта еллар буе больницада ятарга, бөтен канын алыштырырга кирәк.

Баһадур моны белә һәм ул аңа бармаячак.

Бу авыруны ул дәвалап булмаячагын белә.

Аллаһтан куелган тәкъдир сәгате үз вакыты җиткәч туктарга тиеш иде.

Һәм Баһадур ул сәгатьнең кайчан тукталачагын сизенә. Ул шуңа әзерләнә. Шуңа күрә кадерле вакытын бары тик шушы сынауга әзерлеккә генә бирә.

Менә бүген дә ул, клубтан чыккач, мәктәп ишегалдына кереп, намазга әзерләнә башлады. Япон галимнәре биредә торганлыктан, Баһадурның ярты гомере шушында алар белән үтә иде. Мәктәптән мәчеткә дә якын, Баһадур шушында юынып тәһарәтен ала да бабасы янына мәчеткә кереп китә. Бүген дә ул шулай итте. Клубта күргән хәлләрдән, түрәләрдән ишеткән ялганнан соң, аның чистарынасы, болардан бөтенләй арынасы килде. Кулларын, битләрен юды, авыз-борыннарын яхшылап чайкады, җиңнәрен сызганып, терсәкләрен юды, башын, колакларын су белән чылатты, иң соңыннан аякларын яхшылап юды. Һәр хәрәкәте саен Аллаһны искә алды, Аңа зекер итте. Үзен бик зур игътибар белән күзәтеп торган карт галимне соңыннан гына күрде.

— Син һәр намазга шулай әзерләнәсеңме, улым? — дип сорады галим, бик гаҗәпләнеп.

— Әйе, Галим сан, һәр намазга шулай әзерләнәм. Чөнки Аллаһ каршына басам бит.

Карт галим бу сүзләрдән тетрәп китте.

Нинди тирән ышаныч бу баланың сүзләрендә! Нинди олы ярату һәм буйсыну. Әйтерсең лә ул вакыт пәрдәсе аша башкалар күрмәгәнне күрә, башкалар эшләмәгәнне эшли. Кешелеккә ни кирәген белеп эшли. Әлбәттә, беренче урында үзеңне бу дөньяга барлыкка китергән Затка рәхмәт әйтү, гыйбадәт кылу булырга тиеш. Моны әллә кайдагы караңгы бер авылда белә-

ләр, ә дөньяның иң алга киткән илләрендә — юк... Шул исәптән аның илендә дә... Шул исәптән ул үзе дә...

Баһадурның клубта сөйләгән сүзләрен ул тетрәнеп тыңлады.

Ул аның бөтен бәгырен айкап ташлады, үткәннәрен һәм киләчәген ачып күрсәтте. Атом утларыннан исән калган галим аннан миллион тапкыр көчлерәк җәһәннәм уты барлыгын белде. Үзенең моңа әзер түгел икәнлеген аңлады.

— Без дә шулай, юынып, Аллаһ каршына баса алабызмы, улым? — дип сорады ул Баһадурдан, тирән кичерешләр белән.

— Әлбәттә, баса аласыз, — диде Баһадур, яктырып китеп. — Һәм басарга кирәк тә, Галим сан. Безнең динебездә көчләү юк, әмма без кешегә хакыйкатьне җиткерергә тиешбез. Сез бик яхшы кеше һәм сез җәннәттә булырга тиешсез. Әмма моның өчен Аллаһның барлыгын тану һәм Ул әйткәнчә яшәргә кирәк. Намаз-гыйбадәт кирәк.

Карт галим уйга калды. Ул бу дөньяның үзеннән-үзе генә барлыкка килмәвен белә иде. Бу хәтле камил, төгәл системага буйсынган дөньяны, җир-күкләрне, тереклек дөньясын, кешенең үзен бары тик Илаһи Зат кына барлыкка китерә ала. Галим боларга ышана, әмма ул үлгәч икенче дөнья барлыгына әле ышанып бетә алмый. Бу аның фикерләвенә, фәлсәфәсенә туры килеп бетми кебек.

— Әйе, мин дөньяны Илаһи Зат барлыкка китерүенә ышанам, — диде ул, бик җитди итеп. — Бар андый көч. Кемдер аны Аллаһ ди, кемдер Бог дип атый. Ул барыбыз өчен дә бер инде. Мин моңа ышанам. Ә син сөйләгән кыямәт көне турында бөтенләй белмим икән. Шуңа күрә боларга ышанып та бетеп булмый.

— Ә болар берсе икенчесенә бәйләнгән бит, — дип, аңа сабыр гына аңлата башлады Баһадур. — Аллаһы Тәгалә бу дөньяны һәм безне максатсыз барлыкка китермәгән бит. Ул бар икән һәм безне барлыкка китергән икән, аның бездән соравы да булачак. Без бу кыска дөньяда Аның сынавын гына үтәбез. Ә теге дөньяда, ягъни ахирәттә, шушында ничек яшәвебез турында Аллаһ каршында җавап тотачакбыз. Һәр сүзебез, һәр гамәлебез өчен. Һәр минутыбыз, һәр көнебез, бөтен гомеребез өчен...

— Логика бар, — дип, уйчан гына әйтеп куйды япон галиме. — Һәм шулай дөрес тә булачак. Югыйсә җир йөзендә күпме явызлык эшләнә һәм моның өчен беркем җавап бирми. Тыныч кына бу дөньядан китеп баралар. Димәк, алар бу явызлыклары өчен башка дөньяда тотылачаклар, җавап бирәчәкләр?..

— Һәм болар өчен мәңгелек утта — тәмугта яначаклар, — дип өстәп куйды Баһадур.

— Безне бу дөньяда терелләй утка тотучылар да, сезне терелләй кабергә кертүчеләр дә, — дип дәвам итте япон карты. — Һәркем һәрнәрсә өчен җавап бирергә тиеш.

Аларның сөйләшкәннәрен башкалар да зур игътибар белән тыңлап тора иде. Японнар, гомумән, бик җитди халык, хаклыкка ышансалар, икеләнмичә аның артыннан бара торган кавем. Бу юлы да аларга Баһадурның сүзләре, аның яшәү рәвеше, иң мөһиме, аның хаклы булуы бик нык тәэсир итте. Әмма, ни кызганыч, алар тиздән аерылырга тиеш иде. Япон карты күпме генә үгетләп караса да, Баһадур алар белән китәргә ризалык бирмәде. Инде бу кичне булса да алар бергәләп уздырырга булдылар. Баһадур мәчеткә җыена башлагач, япон карты да аның белән бергә гыйбадәт кыласы килүен әйтте. Аңа башкалар да кушылды. Мәктәп ишегалдында алар өчен әзерләнгән махсус юынгыч душта Баһадур аларга тәһарәт алу тәртибен күрсәтте, японнар аның артыннан кабатлап бардылар. Аннан, зур бер очрашуга, эшкә әзерләнгән кебек, барысы да чиста киемнәрен киделәр, Баһадур белән бергә мәчеткә юнәлделәр...

Ни гаҗәп, бүген мәчеттә кеше күп иде. Югыйсә атна уртасы бит, гает-фәлән түгел, ә ярты авыл халкы, ир-ат кубарылып мәчеткә килгән. Бүген көндез клубта булган хәлләр аларны шулай тетрәндергән идеме, Баһадурның өзгәләнеп аңлатуы шулай көчле тәэсир иттеме — Караболак халкы мәчеткә кичке намазга килгән иде. Алар үзләренең кая күченәселәрен аңлый башлаганнар иде. Баһадур аларның алдына чыгып басып, көчле күкрәк тавышы белән шаулатып азан әйтте. Бүген Караболак халкының имамы ул иде. Күпләр аның белән беренче һәм соңгы намазларын укыйлар иде.

Беренче рәткә Таһирҗан бабай һәм авыл картлары басты. Икенче рәткә япон галимнәре тезелде. Алардан соң урта буын, авыл ирләре басты.

Авыл өстенә моңлы Коръән авазы яңгырады. Ул халыкны иманга килергә чакыра, кисәтә һәм хәбәр бирә иде. Соңгы сәгать турында, соңгы җавап турында. Ул халыкны бөек күченешкә әзерли иде. Кемнәр өчендер бу — беренче намаз, кемнәр өчендер инде соңгысы иде... Төнге авыл өстенә Аллаһның кисәтүле сүзләре яңгырый.

«Кешеләрнең кылган фәхеш, хәрам эшләре сәбәпле җир өсте вә диңгезләр өсте бозылды, Аллаһтан җәза йөзеннән каты ачлык, йогышлы каты чирләр заһир булды — кылган бозык эшләренең бәгъзе гөнаһларына дөньяда ук газапны татытмаклыгыбыз өчен. Шәт, бозыклыктан яхшылыкка кайтырлар, иман китереп һәм тәүбә итеп, төзәлеп мөселман булырлар...»

«И мөэминнәр, сезгә ирешкән бәла-казалар вә кайгылар

үзегез кәсеп иткән гөнаһларыгыз сәбәпледер, шулай булса да Аллаһ гөнаһларыгызның күбрәген гафу итәдер...»

Караболак тетрәнеп бу сүзләрне тыңлый.

Мәчет манарасы аша күктән иңгән тавыш һәр йортка үтеп керә, һәр кешенең күңелен шакый, һәркемнең йокысын кача чыра.

И кешеләр, әзерләнегез, әзерләнегез, тиздән бөек күчеңү булачак...

Өлгерергә ашыгыгыз... Өлгерергә ашыгыгыз...

Караболак өстенә тәгәрәп төшәрлек булып тулган ай карап тора. Ул биредә бик күп вакыйгаларның шаһиты булды. Хәзер дә ул күкне тутырып авыл өстенә төшеп килгән фәрештәләрне күрә. Алар бу төндә бер изге җанны җирдән мәңгелеккә алып китәчәкләр. Бу төндә Караболак өстендә күк капкалары ачылачак. Шул капкалар аша изге җан күккә ашачак...

Мәчеттән төнге урамга чыккан халык аптырап калды — күк йөзе көндезге кебек яп-якты иде. Юк, бу көндезге яктылык та түгел, бу — көмеш нурга күмелгән зәңгәр моң иде. Һәм күкнең капкалары ачылган. Җиде галәм чиген үтеп, җиргә җәннәт нуры килә, фәрештәләр иңә. Җан тетрәткеч бу илаһи күренештән халык җиргә ава, тезләнеп дога кыла башлый. Караболак өстендә күк капусы ачыла...

Баһадур үзенең инде шул юлдан китеп барганын күрә. Ул фәрештәләрнең ни өчен, кем артыннан килгәннәрен белә...

Ул Таһирҗан бабасы белән кочаклашып бәхилләшә, башка авылдашлары, танышлары белән хушлаша. Күктән иңгән көмеш нур инде аның тирәсендә генә кала, ул шул яктылыкта төнге авыл урамы буйлап китеп бара. Ул соңгы тапкыр Караболак урамнары буйлап үтә, әйтерсең лә һәр йорт, һәр агач, һәр үлән белән бәхилләшә. Ул, карашына сыйдырып бетерергә теләгәндәй, үзе белән мәңгелеккә дә алып китәргә теләгәндәй, Караболак өстенә карый. Бу — аның туган җире, әти-әнисенең, әби-бабасының кендек каны тамган җир. Борынгы татар бабалары, беренче Алып кешеләр тезләнеп намаз укыган изге җир. Баһадур бу җирнең җылысын бөтен җаны-тәне белән тоя. Ул аның инде мәңгелеккә үзеннән каласын да белә. Ул шушы туфрактан мәңгелеккә китәргә тиеш — тәкъдир китабына шулай язылган...

Иртән Баһадур мәчеткә азан әйтергә килмәде.

Ул иртәнге намазда да күренмәде.

Иртәнге намазны Таһирҗан карт үзе укытты.

Күңеле нидер сизенеп, намаздан соң ул Хәбирә карчыкларга китте. Баһадурның һаман тормавына Хәбирә карчык та борчылып йөри иде, алар Таһирҗан карт белән аның яны-

на килделәр. Баһадур күккә карап елмаеп ята, әйтерсең лә анда рәхмәт фәрештәләрен күргән. Йөзе бераз агарып киткән, аңардан бөтен йортка ниндидер яктылык сирпелеп тора. Баһадур яткан бүлмә эче исә моңа кадәр таныш булмаган хуш ис белән тулган, әйтерсең лә биредә әле генә җәннәт фәрештәләре килеп киткән...

Таһирҗан карт эшне шунда ук аңлады.

Изге кеше, җәннәт әһеле генә дөньядан шулай китә ала иде...

— Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигуун, — диде ул, онытынның озын кефекләрен йомдырып. — Барыбыз да Аллаһтан килдек һәм Аллаһка кайтабыз.

Карт белән карчык, Баһадур янына утырып, озаклап дога кылдылар...

Инде бу хәбәрне аның ата-анасына җиткерергә кирәк иде.

Инде, утлы шардай тәгәрәп, Караболак өстенә кояш чыгып килә.

Баһадурның җаны инде, җиде галәм чиген үтеп, җиде җиһан капкасын кичеп, күккә ашкан иде...

## Унсигезенче бүлек

Әллә Караболактан бик дулкынланып кайтканга, әллә башка сәбәп белән, Гөлҗиһан бу төндә йоклый алмады. Аның күз алдына һаман Караболак клубында бөкрәешеп утырган авылдашлары килде. Сәхнәгә менеп кунаклаган тук түрәләр каршына килеп басты. Ул яңадан улы Баһадурның агарып калган йөзен, Таһирҗан бабасын, әнисен күргән кебек булды. Төне буе аның янына Рәшидә, йөгереп килеп, һаман дару сорады, үлә алмыйча ятам бит, дип зарланды...

Гөлҗиһан үзе дә авырый иде. Ул әллә ничә тапкыр торып дару эчте, тәне һәм җаны сызланудан, бүлмәдән бүлмәгә йөрде. Фәргатьнең дә хәле яхшы түгел, күпме дару эчсә дә, ул да йокыга китә алмый, сызлана. Болай булса, иртәгә больницага салмыйча да булмас. Бәлки, үзе дә кереп ятар, чөнки йөрәге бөтенләй зәгыйфьләнде, Гөлҗиһанга буйсынмый башлады. Баһадур авылда вакытта, икесенә дә бераз рәтләнеп алырга кирәк...

Шундый уйлар белән Гөлҗиһан тәрәзә янына килеп басты.

Шәһәр, ниһаять, төнге йокысына китеп бара, күп тәрәзәләрдә утлар сүнгән. Күлнең теге ягы яктырып тора, анда завод торбалары төне буе утлы ялкыннар чәчеп утыралар. Кара урманнар аша каерылып, Гөлҗиһан Караболак ягына карады һәм имәнеп китте: авыл өстендә күк яп-якты булып

ачылган һәм Караболакка таба көмеш юл сузылган иде. Гөлҗиһанның тыны кысылды, ул балконга йөгереп чыкты һәм Караболак ягына текәлде. Әйе, ул ялгыш күрми — авыл өстендә тагы күк капусы ачылган иде. Аның баласы, анасы өстендә, Караболак турында күк үзенең капкаларын киереп ачып куйган иде...

«Нидән булыр бу? — дип уйлады Гөлҗиһан дулкынланып. — Төн уртасында нинди хәбәр бу? Хәерлегә булсын, ни булса да, ахыры хәерле булсын...»

Эчке якта авыр итеп ыңгырашкан тавыш ишетеп, Гөлҗиһан йөгереп бүлмәгә керде. Фәргатьнең хәле бөтенләй начарланган, ул саташып, бәргәләнеп ята. Гөлҗиһан тизрәк аның кан басымын үлчәде, йөрәк тибешен тыңлады — алар коточкыч дәрәҗәдә иде. Ул арада Фәргать берничә тапкыр аңын да җуйды, Гөлҗиһан биргән дарулар, ясаган уколлар аңа инде ярдәм итми иде. Гөлҗиһанның ирен әле беркайчан да мондый авыр хәлдә күргәне булмады. Ул үзенең авыртусызлануларын да онытып җибәрде, соңгы көчен, егәрен җыеп, ирен коткарырга ташланды...

Гөлҗиһан, тиз генә үзе эшли торган больницага шалтыратып, аннан «ашыгыч ярдәм» машинасы чакыртты. Бәхетенә, машина бик тиз килеп җитте, Фәргатьне носилкага салып, алып чыгып та киттеләр. Гөлҗиһан больницага үзе барды, Фәргатьне аерым палатага салдырды, иренә беренче ашыгыч ярдәмне дә үзе күрсәтте. Әмма Фәргать аңына килмәде, мәет кебек тынсыз-өнсез ята бирде. Ул арада табиблар да җыелып өлгерде, алар Фәргатьне коткару өчен ашыгыч чаралар күрә башладылар. Тиз арада ясалган кайбер анализлар күрсәткәнчә, Фәргатьнең ашказаны асты бизе эшләми башлаган иде, ул исә бөтен эчке органнарга тәэсир иткән. Ашыгыч рәвештә операция ясамасаң, аны алып калып булмаячак иде. Аңа тиз арада көчле дарулар керттеләр, система астына салдылар һәм операциягә әзерли башладылар. Гөлҗиһанның үзенең дә хәле бик начар иде, ул берничә тапкыр аяктан егыла язды, учлап дару эчте, көчле уколлар ясатты. Ни генә булса да, аңа бүген ире яныннан китәргә ярамый. Операциядә ул үзе дә катнашырга тиеш иде.

Ул арада сызылып таң да атты, Иртәшне җәйге кояш нурлары күмеп китте. Операциягә хәтле Гөлҗиһан авылга шалтыратып, әнисенә мондагы хәлне әйтергә булды. Дөньянықын белеп булмый, балаларның җыела торуы кирәк иде. Әтиләре исән вакытта Баһадур да, Гадел белән Гадилә дә Иртәшкә кайтып җитәргә тиешләр. Гөлҗиһанның үзенең дә хәле бик начар, янда балаларның булуы кирәк...

Авылда нигәдер трубканы Таһирҗан карт алды.

«Бәлки, бездә кунып калгандыр, — дип уйлады Гөлҗиһан бабасы турында. — Аның туры килүе яхшырак та әле... Әни борчылыр иде мондагы хәлләрне белсә...»

— Фәргать авырып китте әле, Таһирҗан бабай, — диде ул, исәнләшү белән. — Төнлә больницага салдык. Хәзер операция буласы. Хәле әйбәт түгел, балаларның кайта торулары хәерле. Баһадурны хәзер үк Иртәшкә озатыгыз әле, туптуры монда, больницага килсен.

Әмма аның сүзләренә Таһирҗан карт берничек тә җавап бирмәде.

Картның дәшмәвенә Гөлҗиһан аптырабрак калды, чөнки аның озаклап сөйләшеп утырырга вакыты юк иде. Фәргатькә операция башланырга тора, Гөлҗиһанның һәр минуты санаулы. Әллә соң бабасы аның ни әйткәнен аңлап бетмәдеме икән, ишетмәдеме? Ни әйтсәң дә, йөз яшьлек карт бит инде ул.

— Таһирҗан бабай, Баһадурның үзен бир әле, — диде ул, башта ук шулай эшләмәвенә үкенеп. — Үзенә тизрәк аңлатырмын.

Ниһаять, Таһирҗан карт телгә килде:

— Баһадур юк инде, кызым, — диде ул, бик ерактан килгән тонык тавыш белән.

Аның бу сүзләреннән, хәсрәтле тавышыннан Гөлҗиһанның аяк астында җир шуып китте, аумас өчен, ул стенага сөялде.

— Ничек юк? Син нәрсә сөйлисең, Таһирҗан бабай? Нәрсә булды Баһадурга? Кая китте? Ни булды?!

— Сабыр бул, кызым. Сабыр ит. Аллаһыдан сабырлык сора. Баһадур вафат. Бу төндә күзләрен йомган...

Гөлҗиһанның күз алдында больница бинасы чайкала башлады. Аннан идәне, түшәме, стенасы — барысы бергә Гөлҗиһан өстенә гөрселдәп җимерелеп төште.

Аннан шәһәрнең асты өскә килде, барысы да караңгы бушлыкка убылды...

Гөлҗиһан өчен дөнья бетте. Чөнки аның баласы үлгән иде. Баһадуры. Улы.

Кайгыдан ул кычкыра да, елый да алмады.

Бу хәсрәттән ул яши дә, үлә дә алмады. Аны, аңын җуйган хәлдә, үз бүлмәсеннән табып алдылар...

Күрше бүлмәдә аны тагы бер мәет — иренең үле гәүдәсе көтеп тора иде. Фәргать, операцияне көтмичә, йөрәге туктап, үлеп киткән иде...

Гөлҗиһанга берьюлы ике мәетне — ире белән улын кара җиргә тапшырырга кирәк иде. Һәм шушы хәсрәтләрдән исән калырга кирәк иде...

Икенче көнне чәчләре ап-ак булып агарып чыккан Гөлҗиһан, иренең мәетен алып, Караболакка кайтып китте...

Анда аны улының үле гәүдәсе көтеп тора иде. Таһирҗан карт аларны үзе юды, кыйблага каратып, үзе җирләде, үзе җеназа укыды...

Бу кайгыларны күтәрә алмыйча, шул көннәрдә Гөлҗиһанның әнисе Хәбирә карчык та үлеп китте. Таһирҗан карт аны, кыйблага каратып, үзе күмде, үзе җеназа укыды.

Гөлҗиһан бу кайгылардан сыгылып төште, күзләренең нуры сүнде, яшәвенең яме бетте. Ул алга таба ничек яшәргә, ни өчен яшәргә кирәген үзе дә белми иде.

Ә яшәргә кирәк, тәкъдирдән бирелгән вакытны яшәп бетерергә кирәк иде...

Әмма ничек?! Сөйгән ире юк, яраткан улы юк, газиз әнисе юк. Ничек итеп дөньяда яшәргә шулардан соң?

«Ә без?»

Тукта, бу аның телсез-чукрак балалары шулай эндәшә түгелме соң? Йөрәкләре, күңелләре белән аңа эндәшәләр, ялыналар, ялваралар. Аларның да бит Гөлҗиһаннан башка беркемнәре дә юк. Алар да бу дөньяда япа-ялгыз бит — атадан калган ятимнәр.

Гөлҗиһан үзе дә ятим, балалары да ятим, Караболак халкы да ярдәмчесез, ятим. Бу кара илдә алар барысы да ятимнәр икән шул, ятимнәр. Шуларны яклау өчен булса да, бу дөньяда яшәп бетерергә кирәк иде.

## Унбишенче бүлек

Гөлҗиһан бу хәлләрдән бик озак аякка баса алмады...

Ул озак кына больницада ятты, эшкә ярамыйча, инвалидлыкка чыкты. Аның бавыры шешеп дүрт-биш тапкыр зурайган, йөрәге яртылаш кына эшли башлаган, бизләре махсус даруларсыз тора алмый, канын да гел алмаштырып торырга кирәк иде. Инде бу газаплы дөнья белән мәңгелеккә хушлашам, тынычланып калам дигән чакларында, ул гел ике ягында ике баласын тойды. Әйтерсең лә ике ягындагы ике фәрештәсе. Алар Гөлҗиһанның кайгылы кара тормышын якты нур белән тутыралар, йөрәк тавышлары белән аны упкын авызыннан тартып алырга тырышалар иде. Инде үлдем, инде беттем дигәндә, Гөлҗиһан балаларының ыңгырашкан авазларына айнып китә, алар, сөйләшә алмагач, үксеп-ыңгырашып булса да әниләрен үлем тырнагыннан тартып алырга азапланалар иде. Телсез балаларының җан авазы, сүзсез өне Гөлҗиһанны уятып җибәргән кебек булды. Күзләрен ачкач, ул аларның мөлдерәп торган карашларын күрде, мондый әрнүле караш, мөгаен, телсез кешеләрдә генә буладыр. Сүз белән әйтә алмаганны алар күзләрендә чагылдыралар, кулла-

ры, бармаклары белән булса да үзләренең әниләрен өзелеп ратуларын аңлатырга тырышалар.

Гөлҗиһанның Баһадурдан тыш тагы ике баласы бар иде. Һәм ул шулар хакына яшәргә, тормыш өчен көрәшергә тиеш иде...

Гөлҗиһан бераз аякка баскач, беренче эш итеп, балалар белән Караболакка кайтып килергә булды. Анда аларны газизләренең өч кабере, ялгыз нигез көтә иде. Агачлардан шаулап көзге яфрак коелган көннәр иде бу. Бөтен Караболак өстен көзге моңсулык, көзге тынычлык сарган. Барысы да элеккеге кебек — Караболак та үз урынында тора, Аллакүл чишмәсе дә һаман элеккечә агып ята. Тик монда инде аның газиз әнисе юк, күз нуры улы юк, өзелеп яраткан ире юк...

Гөлҗиһан туып үскән нигез дә ялгыз...

Тирә-күршедә дә ялгыз йортлар күп, тәрәзәләр кадакланган. Кемнәр үлгән, кемнәр киткән. Урамда сирәк-мирәк карткоры очрый, берәм-сәрән генә бала-чага күренә. Гөлҗиһан өчен иң авыры — ялгыз йортка кайтып керү. Әнисе аны һәрчак чәй куеп, болдырга чыгып каршы ала иде. Хәзер болдыр буш. Әмма... Әмма ишек ачык! Ә түрдә, өстәлдә, нәкъ теге вакытлардагы кебек, самавыр гөжләп утыра... Моны күреп, Гөлҗиһан сискәнеп китте, саташам, ахры дип уйлады... Ул арада чаршау артыннан Таһирҗан карт күренде, ул ашыкмый гына табын әзерләп йөри иде. Аны күргәч, Гөлҗиһанның бөтен кайгылары онытылып китте, бу дөньяда аның иң кадерле кешесе — Таһирҗан бабай бар иде бит! Әле ярый ул бар иде. Әби-бабасы, әти-әнисе урынына калган изге зат бар иде.

Кочаклашып күрештеләр, елашып та алдылар. Алып кайткан тәм-томны өстәлгә бушатып, элеккеге кебек бергәләп чәй эчә башладылар. Бу өйдә, бу нигездә әйтерсең лә берни үзгәрмәгән. Адәм баласына бәхетле булу өчен менә шушы туганлыкны, якынлыкны тою да бик җитә иде... Бигрәк тә авыр вакытларында... Бигрәк тә ялгыз калганда...

— Менә шулай ике йорт арасында йөрим әле мин хәзергә, — диде Таһирҗан карт, түр башына менеп утырып. — Өч йорт дисәң дә була, әле каршыда төп йорт та бар бит...

— Өлгерә алгач, бик яхшы инде, Таһирҗан бабай! Алланың рәхмәтләре яусын сиңа, йортны ташламагансың. Ничек итеп буш йортка кайтып керермен, дип, бик борчылган идем. Күңелем һаман ияләнә алмый бит әле бу югалтуларга, Таһирҗан бабай. Бигрәк бер-бер артлы китеп бардылар бит — Баһадур, Фәргать, әни... Инде урыннары җәннәттә булсын җаннарымның. Бигрәк оныта алмыйм бит, Таһирҗан бабай. Үзәкләрем өзелә. Янымда бу балалар булмаса, аякка да баса алмаган булыр идем. Аллаһы аларны сәбәпче итте күзлә-

ремне яңадан ачарга, яңадан яши башларга. Бигрәк авыр бит, Таһирҗан бабай, бигрәк авыр бит. Ничек яшисе булыр алга таба.

Гөлҗиһан, алдындагы чәен дә онытып, сулкылдап елый башлады. Бу хәлләрдән соң аңа, туган нигезенә кайтып, бер еларга, бушанырга кирәк иде. Таһирҗан карт сабыр гына аның елап бетерүен көтте. Игезәкләр тагы сагаеп, хәвефләнеп калдылар, әниләре янына килеп, тавышсыз гына аны юата башладылар. Бераздан Гөлҗиһан үзе дә тынычланды, чөнки күз яшьләре белән генә берни үзгәртеп булмаячагын ул үзе дә аңлый иде.

— Бередән мәчеткә дә якын, сезнең кайтып килүегезне дә гел көттем, шуңа күрә бередә яши башладым әле, кызым, — дип дәвам итте Таһирҗан карт, Гөлҗиһан бераз тынычлангач. — Үзебезгә Чечнядан кайткан бер гаиләне керттем, яшь балалары белән. Бигрәк кызганыч хәлдә бит кешеләр.

Бу хәбәрдән Гөлҗиһан аптырап китте.

— Караболакка кайтучылар да бармыни? — диде ул гаҗәпләнеп.

— Ә кая барсыннар, анда сугыш бит. Тумышы белән безнең авылдан ул егет, әнисе Караболакныкы булган, чечен кешесенә кияүгә чыккан булган. Хәзер аларның нәселе үлеп бетте инде монда, сугыш та кирәк булмады... Шул егет, әнисенең әйткәннәрен истә тотып, хатынын, балаларын алып, монда кайтып егылды. Сугыш гарипләндергән инде — бер аягы юк. Әмма бик тәкъва мөселманнар үзләре, барысы да намазлы. Хәзер мәчеттә мине дә алыштыра башлады, намазларны да укый, җеназалар да үткәрә.

— Алар монда радиация икәнлеген, яшәргә ярамаганын беләләрме соң, бабай? — диде Гөлҗиһан, тагы да аптырап.

— Беләләр, кызым, беләләр. Әмма кая барсыннар? Чеченнарга бер җирдә дә көн юк бит. Аларны шәһәрләргә дә кертмиләр, авылларга да якын җибәрмиләр. Йорт-җирләре Грозныйда бомба астында калып беткән. Әти-әнисе шунда үлеп калган... Әле ничек монда кайтырга башлары җиткән. Тик балалары бик курка торганга әйләнеп калган, авыл өстеннән самолет очып үтсә дә, елап кача башлыйлар. Менә нинди хәлгә китерәләр бит адәм баласын, кызым. Нинди ил бу, нинди ил?! Кемне тереләй агулап үтерәләр, кемне бомбага тоталар. Боларга без беребез дә кирәк түгел икән бит, җирләребез, байлыгыбыз гына кирәк икән...

Кеше кайгысы янында Гөлҗиһанның үз хәсрәте кечерәеп калган кебек булды. Әле аның торырга урыны бар, янында ике баласы, кайтып егылырга туган авылы бар. Киңәш итим, таяныйм дисә, якын кешеләре бар, әүлия кебек бабасы бар. Ә дөньяда күпме кеше илсез-җирсез, йортсыз-кадерсез

булып көн күрә бит. Бөтен җирдән куылып, эзәрлекләнеп яшәргә мәҗбүрләр...

— Үзеңә сыендырып, яхшы эшләгәнсең, бабай, — диде ул. — Кирәк тапсаң, монда да кертә аласың. Без бит кайтып-килеп кенә йөрибез инде, барыбер монда тормыйбыз.

— Рәхмәт, кызым. Дөньянықын белеп булмый. Бәлки, башкалары да килеп төшәр, ярдәм итәргә кирәк ул халыкка.

Шулай сөйләшә-сөйләшә, бакча якларына чыгып керделәр. Бөтен җир ялт иткән, бәрәңгеләр алынган, яшелчә-җимеш җыелган, агачларына хәтле бәйләп, тәртипкә китерелеп куелган иде.

— Бәрәңгеләргә хәтле алып куйгансың, рәхмәт инде, Таһирҗан бабай, — диде Гөлҗиһан, күңеле йомшарып.

— Шул чеченнар булышты, — диде бабасы. — Эшкә бик булган, тәртипле халык алар. Эчүнең нәрсә икәнен белмиләр, аңа якын да килмиләр. Болар артыннан тагы берничә гаилә киләсе булган Караболакка, күршедәге урыс авыл советы аларга рөхсәт итмәгән. Имеш, бу авылның үзенең дә алдагы язмышы билгеле түгел әле, дип кире борганнар. Күчерә калсалар, башка бәла булыр дип куркалардыр. Югыйсә күпме йорт буш тора бит, яшәсеннәр иде рәхәтләнеп. Юк, чеченнардан хәтта бу агулы җирләрне дә кызгана Рәсәй дәүләте...

— Күчерү турында яңадан сүз булмагандыр бит, Таһирҗан бабай?

— Юк, кызым, теге вакытта халык башын гына бутап китте бит алар. Яңадан күренмәделәр берсе дә. Мәскәү, Чиләбе телевизоры берничә тапкыр күрсәтте Караболакны, имеш, халык үзе күчәргә теләми дип баралар. Шуның өчен генә оештырылган иде бит ул уен. Була торган нәрсә түгел ул, кызым. Бигрәк тә хәзер. Эт — баш, сыер — аяк бит хәзер, бер җирдә тәртип юк...

Тагы бер кат чәйләр эчеп, җыештырып куйгач, авылны, зират буйларын әйләнеп кайтырга булдылар. Таһирҗан бабай исә өйләренә кайтып китте, бүген дә берничә йортта мәет бар икән, җеназаларны чечен егете укыгач, халык аңа килә башлаган. Таһирҗан карт хәзер аңа ярдәм итеп, киңәш биреп кенә тора. Хәзер дә ул өенә ашыкты, ул әле бүген кайсы йортта мәет барлыгын да белми иде. Мәчеттә очрашырга килешеп, алар аерылды. Гөлҗиһанны урмандай шаулап утырган Караболак зиратлары көтә иде... Газизләренең әле туфраклары да суынып өлгермәгән каберләре көтә иде...

Бу зиратларның хәзер очы-кырые күренми.

Гөлҗиһан үскәндә бер генә зур зират иде, хәзер инде аларның хисабын белүче дә юк. Араларына койма коручы да юк, чөнки бу зиратлар күптән кушылып тоташ урманга әйлән-

гәннәр инде. Татарда зиратка агач утырту гадәте бар, кешеләр якыннарының каберләрен күп вакыт шул агачлардан эзләп табалар. Әби-бабасының каберенә карагай агачы утыртканнар иде. Каядыр эчтә Хәбибулла абыйның кабере калган булырга тиеш. Әтисе дә шулар арасында ята, аның да кабере өстендә инде шактый ныгыган карагай агачы шаулый. Менә монда — койма буенда гына өч кабер — аныкылар. Әнисе, ире, улы... Алардан соң да инде яңа каберләр шактый күренә. Гөлҗиһанның энеләре кайтып өчесенә дә кечкенә генә таш куйдырып киткәннәр, аларга да карагай үсентеләре утыртканнар. Бөтен нәселгә бертөрле булсын, дигәннәрдер инде. Тиздән Гөлҗиһан үзе дә биредә ятар, аның каберендә дә карагай агачы шаулап утырыр...

Бу уйлардан күңеле тулып, Гөлҗиһан зират коймасына капланды.

Ул зират эченә кермәде, керсә, шуннан чыга алмас кебек тоелды...

Гадилә дә әнисе янында койма буенда басып калды, Гадел исә эчкә кереп, кабер өсләрен чистартып, карап чыкты. Бу каберләрдә аның әтисе, энесе, әбисе ята. Ә Гадел алар рухына кычкырып бер дога укый алмый, әнисен юатып, бер сүз әйтә алмый. Ул шушы карагайлар кебек телсез. Җанында бушлык. Аның әле тормышта бер генә соравына да җавап таба алганы юк. Ул хәзергә бу дөньяда бик ялгыз.

Гөлҗиһан исә, койма буенда тезләнеп, әрвахлар рухына дога кыла.

Аллаһтан аларның рухларын шат кылуын сорый. Кабер газапларын җиңеләйтүен сорый. Алар белән җәннәтләрдә очраштыруны сорый. Бу әрвахларга хәзер догадан башка берни кирәкми, әнисенә дә, иренә дә, улына да бары тик изге дога гына кирәк. Гөлҗиһанның күзләреннән мөлдерәп яшь ага, шушында ятучылар белән бергә, ул үзенең дә гомере үтеп киткәнен, инде бетеп барганын сизенә. Шуны раслагандай, кара урман кебек, Караболак зираты шаулый, аяк астына соңгы сары яфраклар коела. Әйтерсең лә Гөлҗиһан үз-үзен, үз гомерен шулай соңгы юлга озата...

Зиратның теге башында кемнәргәдер яңа кабер казыйлар...

Хәзер инде аларның хисабын да алып бармыйлар. Мөселманча җиргә тапшыралар да тын гына таралышалар. Яннарыннан үтеп барышлый, Гөлҗиһан мәет күмүчеләр кырыенда тукталды, тагы кемнәр үлүен сорады. Зират коймасы буенда җеназа күтәп ятучыларның берсе Рәшидә икәнлеген әйттеләр. Бу хәбәрдән Гөлҗиһанның башлары әйләнеп китте, йөрәгенең тагы бер кылы зыңгылдап өзелде. Әйтерсең лә Рәшидә балалык дусты Гөлҗиһанның кайтып җитүен көтеп

торган, хәзер дә, каберенә дә кермичә, аның янына килеп җитүен көтеп ята. Көзге җил аның битенә япкан ак бәсне җилфердәтә, аның аша Гөлҗиһанга Рәшидәнең инде мәңгегә тынып калган бәхетле йөзе карап ята. Ул инде хәзер авыл буенча «мин үлә алмыйча ятам» дип кычкырып йөрми, дару да сорамый. Ул зираттагы үз өенә килгән, мәңгелек йортына. Аңа инде хәзер берни кирәк түгел. Догадан кала... Хәер, балачактан җиңеләйгән, дөньяда авырлыктан башка берни күрмәгән, беркемгә явызлык эшләмәгән бу бичара җанның нинди гөнаһысы булсын икән. Раббым, инде бу бәндәңә ахирәт көнендә җиңеллекләр бир, дөньяда күргән газапларны анда күрмәсен.

Рәшидә өстенә карап, Гөлҗиһан әнә шундый эчкерсез догаларын укыды. Ул үзенең кайтып җитүенә сөенде, классташының җәсәде белән булса да саубуллашып кала алды, баш очында догасын укыды. Ул арада күмүчеләр дә, башка каберләрдән бушап, Рәшидә янына килеп җиттеләр. Таһирҗан бабай да килеп җиткән, ул бу эшләрне оештырып йөри булып чыкты.

— Бүген таң атканда киткән, бичара, — диде ул, Рәшидә ягына карап. — Хәзер авылда көнгә берничә мәет булгач, вакытында белеп тә өлгереп булмый. Әле ярый хатын-кызлар юып, әзерләп куйганнар, ирләр кабер казып өлгергән. Хәзер менә шушы хәл китте, кызым, көненә берничә мәет. Инде соңгылары.

Таһирҗан карт Рәшидәгә үзе җеназа укыды, үзе аны күмеште.

Гөлҗиһан балачак дусты белән сүзсез генә бәхилләште.

Рәшидә инде барысыннан да котылган иде.

Җеназа беткәч, Таһирҗан карт аңа бер төенчек тоттырды. Аны Рәшидәне юучы карчыклар биргән булып чыкты. Төенчекне Рәшидә үзе исән вакытта ук әзерләп куйган булган, Гөлҗиһан кайткач, аңа бирергә кушкан. Гөлҗиһан калтыранган куллары белән төенчекне чишеп җибәрде. Аннан кара плюш жакет һәм яшел шәл килеп чыкты. Алар өстендә Рәшидә куллары белән язылган дәфтәр ята иде. Ә аның тышына «Рәшидә бәете» дип язылган. Көзге җил Гөлҗиһан кулындагы шакмаклы дәфтәрне җилфердәтә, битләрен ачкалый. Саргайган дәфтәр битләреннән Рәшидәнең балалар кулы белән язып калдырган соңгы сүзләре карап тора. Яңа мәетне күмгән арада, Гөлҗиһан, зират коймасына сөялеп, бәетне укый башлады:

Җәйләргә чыксам, йөрермен, дидем,
Хуш исләр иснәп, терелермен, дидем.
Якты дөньяда йөреп туймадым,
Туймасам да, мин мәңге тормамын.

Гөлҗиһанның күзләренә тагы яшь бәреп чыкты.

Ул Рәшидәнең мәктәптә укып йөргән елларын күргән кебек булды. Бу дәфтәр дә нәкъ шул чордан — илле җиденче елдан калган иде. Рәшидә инде шуннан соң укый алмады, көчле баш авыртуы аны җиңеләйтте, биш класс белем белән калдырды. Ә язуы бер дә үзгәрмәгән, нәкъ шул вакыттагы кебек эре, матур хәрефләр. Рәшидә ул вакытта ук шигырь, бәет чыгарырга бик оста иде бит, стена газетасында гел аның шигырьләре иде. Аның хикәяләрен Казанның балалар газетасы да бастырып чыгарганы булды хәтта. Шушы хәлләр булмаса, бәлки, Рәшидәдән дә менә дигән журналист чыгар иде. Бәлки, язучы булып китәр иде... Чөнки бик ихлас кеше иде бит ул, күңеле чиста иде аның һәм шулай китеп тә барды. Сагынып сөйләргә бәете генә калды...

Озын көннәрдә, салкын төннәрдә
Яткыза безне үлем хәлләре.
Күземне йомсам, күзләрем тала,
Бар якыннарым дөньяда кала.

Яхшылыгымны искә алыгыз,
Җомга көннәрне хәер салыгыз.
Күңелем үсмәде, кулым бармады,
Хәсрәтләр, уйлар миннән калмады.

Авыр булса да, дөнья көтәргә,
Читен хәл икән ташлап китәргә.
Ерак җирләрдән күрергә килегез,
Озатып калыгыз, фатиха бирегез.

Җаным чыкканда, янымда торыгыз,
Шаһәдәт белән үтсен диегез.
Җан чыгулары кичләрдә булса,
Төннәр саклагыз, авырсынмыйча.

Тәнем-буемны үлчәп алыгыз,
Юып пакьләгәч, кәфен салыгыз.
Тәнем бик зәгыйфь, каты тотмагыз,
Кире кайтмамын, ашыктырмагыз.

Хушландырыгыз зифа буйларым,
Бу дөньяларда актык туйларым.
Йокым килмәде озын төннәрдә,
Ризык җыймадым актык көннәрдә.

Иптәш калмаган, түшәк җәймәгән,
Күлмәк тегелгән акбүз җәймәдән.
Караңгы гүргә кемнәр кергезгән,
Кара туфракта черер бу тән.

Бигрәк уфланам иптәшем юкка,
Куеп киткәннәр мәңгелек йортка.
Ялгыз калганмын, исән булыгыз,
Атнакичләрдә дога кылыгыз.

Каберем өстенә таш утыртмагыз,
Агач утыртып, кошлар кундырыгыз.
Каберем өстенә үләннәр үссен,
Гүрем өстенә иманнар төшсен...

Гөлҗиһанның әле беркайчан да мондый бәет укыганы, ишеткәне юк иде. Әйтерсең лә ул Рәшидә турында гына түгел, аның үзе турында да, берәм-берәм дөньядан киткән якыннары турында. Менә бу зиратка күчеп беткән Караболак халкы турында. Һәм моны дивана дип йөртелгән Рәшидә язган. Кышкы озын төннәрдә, көзге пычрак көннәрдә, берьялгызы үлем көтеп ятканда, тән һәм җан газапларын басар өчен, бәет язып калдырган. Юк, ул бит дивана булмаган, мондый шигырь юлларын тиле кеше яза алмый. Ул чарасызлыктан, гаҗизлектән башка дөньяга, башка яшәү рәвешенә күчкән. Аның саф җаны дөньяда барган мәкерне, явызлыкны, алдауны күтәрә алмаган һәм ул үз дөньясына күчкән. Һәм гомер буе үз дөньясында яшәп калган. Мәңгегә киткәндә генә, яңадан бу дөньяга кайтып, васыятен язып калдырган.

Гөлҗиһан акрын гына кайтыр юлга кузгалды.

Яңа каберләр аны тын гына озатып калдылар.

Алар арасында Рәшидәнеке дә бар иде.

Кайтышлый, килешенгәнчә, мәчеткә керделәр. Гөлҗиһан мәчеттә халыкның күплегенә гаҗәпләнде, әйтерсең лә исән калган бөтен халык җомга намазына кубарылып чыккан. Чаршау артында хатын-кызлар да күренә. Гөлҗиһан белән Гадилә шулар янына кереп бастылар, Гадел исә ирләр артына барып басты. Әнисе игезәкләргә мәчеттә кеше нәрсә эшли, шуны эшләргә кирәклеген әйткән, өйрәткән иде инде. Бу хәтле югалтулардан соң, бу хәтле кичерешләрдән соң барысына да җаннарын тынычландырырга кирәк иде. Алардан тилмереп дога көтеп яткан якыннары өчен дога кылырга кирәк иде. Якыннары янына Гөлҗиһан Рәшидәнең дә исемен өстәде, теге дөньяда булса да, рухының шат булуын тели иде ул. Аңа мәңгелек бәхет тели иде.

Намаздан соң Таһирҗан карт аларны теге чечен гаиләсе белән таныштырды. Гөлҗиһан намаз вакытында ук гарәпчәрәк киенгән бу ят хатынга игътибар иткән иде инде. Караболакта болай киенүче юк, аның читтән килгәнлеге күренеп тора иде. Гөлҗиһан уйлаганча, ул чечен хатыны булып чыкты. Намаздан соң алар янына ире дә килеп басты, кечкенә балалары сырып алды. Чечен гаиләсе Гөлҗиһаннарны үзләренә чәйгә чакырды, Таһирҗан бабай да әйткәч, ризалаштылар, җыелышып авылның икенче башына кунакка китеп бардылар.

Бу гаилә Таһирҗан бабайның кечкенә генә өендә өч бала белән яшәп ята икән. Егетнең әнисе татар булса да, ул инде

теге заманнарда ук Караболактан читкә чыгып киткән булган. Казакъстан якларында ул сөргенгә сөрелгән чечен иренә кияүгә чыккан, аннан алар яңадан Чечняга кайтканнар. Муса инде анда туган, бераз татарча аңласа да, чеченча сөйләшеп үскән. Шуңа күрә барысы да аңласын өчен, бүген дә урысча сөйләшергә мәҗбүр булдылар.

— Монда кайтып урнашуыгыз, бер яктан, яхшы булган, энем, ни әйтсәң дә, әниеңнең туган авылы бит, — диде Гөлҗиһан. — Икенче яктан караганда, монда радиацияле үле зона бит, бу хакта сез белеп килдегезме соң яшь балалар белән?

— Әйе, апа, без белеп килдек, — дип җавап бирде Муса. — Без боларны анда күрдек инде. Чечняда бит моннан да куркыныч хәлләр, безнең өстә Россия армиясе бөтенесен дә кулланып карады инде — радиациясен дә, химиясен дә, биологик коралын да. Боларның барысын да тере кешеләр өстендә сынадылар. Анда могҗиза белән исән калган кешеләрнең кайсы — гарип, кайсы — нәселсез, кайсы — мутант, чирле... Нәкъ мондагы кебек. Монда әле бомбага тотмыйлар, кереп атып чыкмыйлар.

— Бездә хәтта Чернобыльгә барып урнашкан чечен гаиләләре дә бар, — дип сүзгә кушылды хатыны да. — Чөнки анда беркем бер сүз әйтми, кумый, үтерми. Россиядә чеченнарны бер җиргә кертмиләр бит хәзер, бөтен җирдән куалар, эзәрлеклиләр, үтерәләр. Ә радиацияле зоналарга безнең арттан керергә курка алар. Үзләренең сәламәтлекләре өчен, әлбәттә. Ә без Аллага тапшырдык инде...

Бу кешеләрнең коточкыч нәрсәләр турында шулхәтле гади итеп сөйләүләреннән Гөлҗиһан куркып китте. Болар үз фаҗигаләрен гадәти хәл итеп кабул итәргә өйрәнгәннәр. Әйтерсең лә алар өчен инде кыямәт көне җиткән. Һәм аларга бу санаулы көннәрен кайда яшәп бетерсәләр дә барыбер иде кебек.

— Яшь балаларыгыз бар бит, шуңа күрә әйтүем иде, — диде Гөлҗиһан, ни әйтергә белмичә.

— Ә монда безгә бик әйбәт, апа, — дип, тагы сүзгә кушылды Муса. — Без үзебезне биредә кеше итеп тойдык. Безнең күптән мондый халәт кичергәнебез юк иде. Кешеләр яхшы монда, шундый ярдәмчелләр, эчкерсезләр. Кешегә карата бернинди шикләнү юк, усаллык, мәкер юк. Минем күптән мондый кешеләр күргәнем юк иде инде. Минем дә тамырларымда шушы татарларның каны ага бит. Мин монда үз өемдә кебек...

— Иң мөһиме — баш очыбызда бомбалар шартламый, торырга йортыбыз, ашарга ризыгыбыз бар, — дип, аны дәвам итте хатыны. — Балаларыбызга да монда бик рәхәт. Үсүләренә мәктәп бар, менә зурысы киләсе елга беренче класска

бара, Алла теләсә. Намаз укырга мәчет бар, әле үзем шунда балаларны, хатын-кызларны җыеп укытып та йөрим, беркем бер сүз әйтми. Безнең өчен бик зур бәхет инде бу, апа. Ә радиация мәсьәләсенә килгәндә, Аллага тапшырдык инде, апа. Алла саклар дип өметләнәбез...

Ул арада каршы яктан балаларның шау-гөр килеп уйнаулары, чыр-чу иткән тавышлары ишетелде. Чечен балалары Гадел белән Гадиләне бик тә үз иткәннәр, итәкләренә үк менеп утырганнар иде. Олы кешеләрнең сөйләшә белмәүләренә, аларга бер сүз дә әйтмәүләренә балалар гаҗәпләнсәләр дә, нигәдер аларны бик яраттылар. Гадел белән Гадилә дә балалар белән мәш килә, әйтерсең лә яңадан сабый чакларына кайтканнар. Моны читтән карап торып, Гөлҗиһанның йөрәге әрнеп, сулкылдап куйды. Югыйсә аларның үзләренең дә менә шушы яшьтәге балалары була ала иде бит инде, ә алар һаман ялгыз. Һаман үз парларын таба алмыйлар. Чөнки бу илдә, бу җәмгыятьтә телсез-чукрак кешегә гарипләр итеп кенә карыйлар. Ә гарипләр гаиләне бары тик үзләре кебек гарипләр, бәхетсезләр белән генә төзи ала. Ә гомер үтә, аның балалары һаман ялгыз...

Кайтып китәр алдыннан, Таһирҗан карт Гөлҗиһанга зур бер тартма бирде. Аны японнар калдырып киткәннәр икән. Ачып карагач, анда Баһадур соңгы көннәрендә эшләгән компьютер булып чыкты. Караболак турында японнар төшергән тасмалар да монда булып чыкты. Тартманы кулына алгач, Гөлҗиһан улына килеп кагылган кебек булды, бу истәлекләр аның өчен сөенечле дә, көенечле дә иде. Аларны Иртәшкә алып кайтып, иркенләп карарга булдылар. Баһадур улы белән тасма аша булса да күрешүне Гөлҗиһан тетрәнеп көтте. Ул улының Караболакка кайткач бик нык үзгәрүен, бөтенләй диярлек икенче кешегә әйләнүен белә иде. Ул аның белән аралашып өлгерә алмады. Соңгы сүзләрен ишетеп өлгермәде, васыятьләрен белмәде. Тасмадагы язмалар Гөлҗиһанга шундый мөмкинлек бирә иде.

Алар, Таһирҗан бабай һәм чечен гаиләсе белән хушлашып, кайтыр юлга чыктылар. Гөлҗиһан, Иртәшкә кайтып җиткәнче, тартманы кулыннан төшермәде, әйтерсең лә ул шул рәвешле нәни Баһадурны кысып кочкан һәм инде беркайчан да кулыннан җибәрергә теләми. Улы белән бу очрашудан ул бераз курка да, нәрсәгәдер һаман өметләнә дә иде. Әйтерсең лә Баһадур аңа нидер әйтергә, нидер җиткерергә тиеш. Моңа кадәр Гөлҗиһан белмәгән, уйламаган нәрсәләр турында хәбәр бирергә тиеш. Исән вакытта әйтә алмаган васыятен хәзер анасына тапшырырга тиеш. Ә Гөлҗиһан әзер булырмы соң аны кабул итәргә? Менә шуңа күрә ул улы белән бу очрашудан каушый һәм дулкынлана иде...

## Уналтынчы бүлек

Баһадур бүлмәсендә хәзер Гадел яши.

Ул, бөтен дөньясын онытып, энесеннән калган техника дөньясына кереп чумды, андагы аппаратуралар белән мәш килә. Япон компьютерына ул могҗизага караган кебек карады, башта шактый вакыт аны өйрәнде, аннан эшләү өчен көйләп җибәрде. Алар өчен, иң беренче чиратта, анда Баһадур язып калдырган сүзләр, аның мөрәҗәгатьләре, фикерләре кирәк иде. Японнар төшергән видеотасмаларда да Баһадурның үзе һәм сүзләре булып чыкты...

Башта Баһадурның компьютерга язып калдырган сүзләрен тыңларга булдылар. Дөресрәге, Гөлҗиһан улының тавышын тыңлады, игезәкләр экрандагы сүзләрне генә укый алдылар. Баһадурның Иртәш, Караболак турында мөрәҗәгатьләре берничә телдә булып, шулар арасында урысчасы да бар иде. Әйтерсең лә Баһадур аларга инде бик ерактан — җиде кат күкләрдән мөрәҗәгать итә. Әйтерсең лә ул анда да Караболак турында, алар турында кайгыртып, борчылып ята иде. Гөлҗиһан улының бу мәсьәләдә ни дәрәҗәдә тирән керүен, аңлавын күреп гаҗәпкә калды. Баһадур бер Караболак турында гына түгел, кешелекнең, дөньяның язмышы турында кайгыртып сөйли иде. Чыннан да, уникe яшьлек бу бала, аның улы, әүлия булган икән. Аның көрәш юлы бик кыска булган, әмма ул әйтәсен әйтеп калдырган. Бөтен дөнья ишетерлек итеп әйткән...

*«...Без, Уралтау татарлары, Нух пәйгамбәр нәселен дәвам итүче төрки халык, Атлантида кебек, атом чоңгылына китеп барабыз...»*

*«Маяк» атом берләшмәсе ябылмаса, сезне дә шул ук хәл көтә...»*

*«Кешелекнең ахыры Урал тауларында башланырга мөмкин...»*

Баһадурның һәр сүзе — кисәтү, дөньяны, кешелекне сакларга тырышу... Аның бу мөрәҗәгате төрле телләрдә һәр кич бөтен дөньяга таралган. Димәк, Караболак турында хәзер бөтен дөньяда беләләр. Баһадур әтисе башлап калдырган эшне дәвам иткән, әнисенә ярдәмгә килгән. Ул «Маяк»ның бөтен Җир шары өчен зур куркыныч тудыруын кисәтә, моны исбатлый, бу хәлдән чыгу юлларын күрсәтә. Ул ашыгыч рәвештә бу үлем комбинатын ябарга чакыра. Менә шуңа күрә Мәскәү, Чиләбе түрәләре, «Маяк» җитәкчеләре көтүләре белән Караболакка килеп җиткәннәр инде, аларга дөнья алдында Баһадурның сүзләрен юкка чыгарырга кирәк булган. Әмма юкка чыгара алмаганнар. Баһадур хәзер инде башка дөньядан кешеләрне аңга килергә чакыра, иманга кайтырга өнди...

Гөлҗиһан тәрәзә янына килеп басты. Каршыда, меңләгән утлары белән җемелдәп, Иртәш шәһәре җәелеп ята иде. Биредә яшәүчеләрнең барысының да язмышлары, гомерләре, тормышлары шушы атом шәһәре белән бәйләнгән. Җир астында исә, аждаһа кебек үкереп, көне-төне дистәләгән атом реакторы эшләп тора, үле күлләр тонып ята, адым саен атом каберлекләре. Бирегә инде бөтен дөньядан тонна-тонна, вагон-вагон атом калдыклары ташыйлар, барысын да Иртәшкә, барысын да «Маяк»ка тутыралар. Ә монда кешеләр ничек яшәргә тиеш соң? Ул хакта беркем дә уйламый. Иң куркынычы — шәһәрдә яшәүчеләр үзләре дә бу хәлгә инде ияләнгәннәр, үлү өчен генә яшиләр кебек. Кешеләргә бу хәлләрне, фаҗигале язмышларын төртеп күрсәтүче юк. Димәк, ире Фәргать башлаган, улы Баһадур дәвам иткән бу эшне туктатырга ярамый. Кешеләргә атом афәте турында аңлатырга кирәк. «Маяк»ның эшчәнлеген туктату мәсьәләсен күтәрергә кирәк. Болай яшәргә ярамавын аңлатырга кирәк. Адәм баласы бу дөньяга газапланып үлү өчен генә тумый бит, аның сәламәт яшәргә, чиста суга, саф һавага хакы бар. Ул радиациядән аягүрә череп үләргә тиеш түгел. Ире Фәргать һәм улы Баһадур башлаган эшне Гөлҗиһан дәвам итәргә тиеш.

Ул, төне буе утырып, суд өчен документлар әзерләде…

Юк, бу юлы ул инде компенсация мәсьәләсен күтәрмәде, хөкүмәттән ярдәм сорамады, Караболакны күчерү мәсьәләсен дә кузгатмады. Чөнки болар барысы да аның өчен вак нәрсәләр булып калдылар, вакытлыча гына булып күренделәр. Чөнки «Маяк» эшләп торганда, барыбер агуланган авыллар да, нурланыш алган кешеләр дә күп булачак, мәсьәләне компенсация яки күчерү юлы белән генә хәл итеп булмаячак. Димәк, мәсьәлә «Маяк»ның үзендә, ул эшләп торганда, монда беркайчан иминлек булмаячак. Димәк, суд каршына да кешеләрнең иминлек мәсьәләсен куярга кирәк, аның өчен «Маяк» атом берләшмәсе, Чернобыль кебек, үзенең эшчәнлеген туктатырга тиеш. Халыкка күрсәткән коточкыч зыяны өчен, меңләгән, миллионлаган кешене рак һәм нурланыштан газапланып яшәргә һәм үләргә дучар иткәне өчен, үзендәге атом калдыклары белән бөтен кешелеккә куркыныч китергәне өчен «Маяк»ның эшчәнлеге туктатылырга тиеш иде. Һәм ул шушы мәсьәләләрне суд каршына куйды…

Аның гаризасын судта бик гаҗәпләнеп алып калдылар…

Аларга әле беркайчан да мондый мәсьәлә белән мөрәҗәгать иткәннәре юк иде. Гөлҗиһанның бу гаризасына җиңеләйгән кешенең бер язмасы кебегрәк карадылар, чөнки «Маяк» эшләмәсә, шәһәр дә бетәчәк иде. Тиешле органнарга күр-

сәтү өчен генә, алар бу хатынның гаризасын алып калдылар. Мондый гаризалар өчен тиле булса — психбольница, акылы булса, төрмә көтә иде. Гөлҗиһан исә халык арасына имзалар җыярга чыгып китте. Әмма әллә үзе җиренә җиткереп аңлата алмады, әллә кешеләр аңларга теләмәделәр, аның «Маяк»ны яптыру турындагы мөрәҗәгатенә бер генә кеше дә кул куймады. Кешеләр аңа куркып, авыруга караган кебек карадылар, аларча, үз акылындагы кеше атом комбинатын яптырам дип йөрми иде...

Гөлҗиһан өенә тәмам арып, алҗып кайтып егылды.

Ул кешеләрнең бу мәсьәләне аңламауларына хәйран калды, атом куркынычының ни дәрәҗәдә зур булуын аңлата алмыйча гаҗиз булды. Ул кергән һәр йортта чирле яки гарип бар, һәрберсе үзендә нурланыш тамгасы йөртә, ә шуларның сәбәпчесе булган атом комбинатын яптыруга тешләретырнаклары белән каршы торалар. Кайда эшләрбез, нәрсә ашарбыз, ничек яшәрбез, диләр... Кешеләрне бары тик шушы нәрсәләр генә борчый иде. Әмма Гөлҗиһан үзенең юлыннан чигенмәскә булды, ул эшне судка хәтле китереп җиткерергә уйлады. Чөнки ул үзенең хаклы булуына чын күңелдән инанган иде. «Маяк», чын мәгънәсендә, бөтен дөньяга үлем нуры таратып ята. Әмма атом аждаһасына каршы бу көрәштә ул берьялгызы иде. Янында янәшә басарлык ире дә юк, улы да...

Кичен бераз ял итеп алгач, ул балалары белән японнар төшереп калдырган видеотасмаларны карарга утырды. Аның бөтен җанын, бәгырен айкап, күз алдына тагы улы Баһадур килеп басты, берәм-берәм авылдашлары үтеп китте. Японнар барысын да бик җентекләп төшергәннәр иде — Аллакүлне дә, таш мәгарәне дә, Алабуга сазлыкларын да, хәтта Караболакның бәрәңге бакчаларын да. Һәм шуларның барысында да Баһадур, Баһадур, Баһадур... Менә ул японнар белән бергә туфракта радиация нормасын үлчи, менә ул судан анализлар ала, авыл халкын тикшерүдә ярдәм итә. Менә ул авыл клубында, менә мәктәптә, менә мәчеттә. Гел үзәктә, гел халык арасында, гел хәрәкәттә. Бу бала исән булса, кемнәр генә булмас иде, нинди дәрәҗәләргә ирешмәс иде. Милләтнең лидеры, ханы булыр иде. Аллаһы Тәгалә аны бу дөньядан алуны кирәк тапкан шул.

Гөлҗиһан балаларына ашыкмый гына шул күренешләргә яңадан кайтырга кушты. Аңа улының һәр сүзе, һәр хәрәкәте бүген җаны кебек кадерле, кирәк иде...

Әйе, теге көнне ул клубтан чыгып киткәч, Таһирҗан бабай да, Баһадур да чыгыш ясаганнар. Японнар да сөйләгән. Баһадур карт галимне русча-татарчага тәрҗемә итеп бара. Барысы да «Маяк»ның халыкка нинди зур зыян китерүен

сөйлиләр, алга таба аның бер Караболакка гына түгел, бөтен кешелеккә куркыныч янавын аңлаталар. Игезәкләр Баһадурның ни сөйләгәнен ишетмәсәләр дә, экранга кереп бетеп, энеләрен карыйлар, хәрәкәтләре буенча ни әйтергә теләгәнен аңларга тырышалар. Ә Гөлҗиһан Баһадурның һәр сүзен, һәр җөмләсен кабат-кабат әйләндереп тыңлый, тыңлаган саен алардан яңа мәгънә таба. Гөлҗиһан шуңа да игътибар итте: Баһадур моңа кадәр беркем әйтмәгән нәрсәләрне әйтә, бу фаҗигаләрнең сәбәбен башкача аңлата. Аның сүзләреннән Гөлҗиһанның үзенә дә куркыныч булып китте. Ул атом фаҗигасенең сәбәпләре никадәр тирән яшерелгәнлеген күргән кебек булды. Үзенең моңа кадәр бу нәрсәләргә игътибар итмәвенә гаҗәпләнде...

Әйе, Баһадур дөрес әйтә — бу җирләр безгә Аллаһтан әманәт иде...

Ә кешеләр аны нишләтте? Агуга, пычракка батырды. Эчәр суын, сулар һавасын, ашыйсы ризыгын харап итте. Табигать белән бергә, иң зур зыянны үзенә салды адәм баласы. Аллаһы Тәгалә тарафыннан мәңгелеккә бирелгән кешелек кодын җимерде, үз-үзен бетерде. Әйе, Баһадур дөрес әйтә — хәзер безнең барыбызда да атом тамгасы инде, әҗәл билгесе. Бу безгә Аллаһның сынавы һәм җәзасы. Без җирдә яшәгән һәр көнебез, һәр гамәлебез өчен Аның алдында җавап тотачакбыз әле. Һәм ул көн тиз булачак.

Улының бу сүзләрен, бу кисәтүләрен ишеткәч, Гөлҗиһан калтырап куйды. Бу сүзләр һәр кешегә кагыла иде. Бу сүзләр Гөлҗиһанның үзенә карата да әйтелгән иде. Гөлҗиһан аларны кат-кат тыңлады, хәрәкәтләр белән игезәкләргә дә аңлатып бирде. Чөнки бу хакта алар да белергә тиеш иде...

*«...Җәһәннәм уты атом утына караганда миллионлаган тапкыр көчлерәк булачак. Әле тәүбәгә килергә соң түгел, әле ялгышларны төзәтергә вакыт бар, әмма тиздән барысы да үзгәрәчәк. Таулар тетелеп күккә очканда, күкләр ишелеп җиргә төшкәндә, җир эчендәге бөтен нәрсәне актарып өскә чыгарганда, дәрья сулары бергә җыелып кушылганда — ул көн киләчәк. Һәм барыбыз да җавап бирү өчен Аллаһ каршына басачакбыз. Һәм без күчәчәкбез... Бу — бөек күчеш булачак. Барыгыз да шул күчешкә әзерләнегез...»*

Баһадурның үлем алдыннан халыкка әйткән соңгы сүзләре.

Дин, Аллаһ, җавап бирү турында...

Бу хакта ул кабат-кабат кешеләрнең исләренә төшерә, кабат-кабат кисәтә. Йа Раббым, ул бит авылдашларын гына түгел, әнисен, үз туганнарын да кисәтә. Ә Гөлҗиһан үзе, аның калган балалары бу күчешкә әзерме соң? Бу сынауга әзер-

ме? Баһадур унике яшендә шуны аңлаган, боларга әзерләнгән, ә Гөлҗиһан, аның игезәк балалары әзерме?

Тасманың соңгы күренешләре Караболак мәктәбендә һәм мәчетендә төшерелгән иде. Биредә дә үзәктә Баһадур, японнар нигәдер гел аны гына төшергәннәр. Менә Баһадур кечке намазга тәһарәт ала, менә ул аның тәртибен японнарга да өйрәтә. Ул аларга үз телләрендә нидер сөйли, тик Гөлҗиһан аларын аңламый. Менә алар бергәләп мәчеткә чыгып китәләр. Ни гаҗәп, мәчеттә халык күп. Һәм Баһадур, азан әйтеп, имам булып, халыкка намаз укыта. Иң алда — кавеменең алдында ул басып тора, әйтерсең лә аларны җитәкләп сират күпереннән алып чыга. Аның артына Таһирҗан бабай һәм авыл картлары баскан, аннан соң — японнар, авыл ирләре. Алар барысы да Баһадурның сүзләрен, Баһадурның хәрәкәтләрен кабатлыйлар, аның артыннан баралар. Күп кешеләрнең күзләрендә яшь, аларның барысында да диярлек әҗәл чире, һәм алар инде бу дөньядан икенчесенә күчеп баралар. Күчеп өлгерергә тырышалар. Авыл өстенә Коръән сүзләре яңгырый, аларны аның улы Баһадур сөйли:

*«Кешеләрнең кылган фәхеш, хәрам эшләре сәбәпле җир өсте вә диңгезләр өсте бозылды, Аллаһтан җәза йөзеннән каты ачлык, йогышлы каты чирләр заһир булды — кылган бозык эшләренең бәгъзе гөнаһларына дөньяда ук газапны татытмаклыгыбыз өчен. Шәт, бозыклыктан яхшылыкка кайтырлар, иман китереп һәм тәүбә итеп, төзәлеп мөселман булырлар...»*

Аннан Баһадур халык белән бергә төнге урамга чыга.

Ә анда — көндезге кебек яп-якты. Караболак турында күк капкалары ачылган, һәм авыл өстенә көмеш нур иңгән. Бу могҗизаны күреп, халык, җиргә тезләнеп, сәҗдәгә китә. Көмеш нур әкренләп Баһадур янында гына кала. Ул барысы белән дә бәхилләшеп, нурлы юлдан китеп бара. Әйтерсең лә шул юлдан күккә аша, инде мәңгелеккә күктә кала.

Гөлҗиһан тасманың беткәнен дә, экранның күптән сүнгәнен дә сизмәде. Ул тирән уй-кичерешләрдә иде. Улы аңа хәбәр калдырган. Улы аңа юл күрсәтеп калдырган. Улы аңа котылу юлын күрсәткән, күченергә әзерләнергә кушкан. Ә Гөлҗиһан әзерме соң аңа?

Гөлҗиһан гомер буе Аллаһка ышанды.

Гомер буе үз көче белән эшләп табып, булганына шөкрана кылып яшәде.

Кешеләргә кулыннан килгәнчә ярдәм итәргә тырышты. Холыксызланмады, ямьсезләнеп, фетнә чыгарып йөрмәде, зина кылмады, аракы эчмәде. Бу сыйфатларны аңа Аллаһы Тәгалә тумышы белән биргән иде. Димәк, Ул аны башта ук шушы яман эшләрдән саклаган. Гөлҗиһандагы бөтен яхшы сый-

фатлар ул — Аллаһтан... Тормышында булган уңышлар — Аллаһтан. Ә югалтулар, газаплары, әрнүләре?.. Димәк, болары да Гөлҗиһанның тәкъдирендә ул туганчы ук язылган булган, аңа шушы сынаулар аша үтәргә кирәк булган. Һәм кеше булып калырга. Нинди шартларда да кеше булып калырга...

Караболакта кеше булып калу дигән сүзгә бик зур мәгънә салалар.

Кеше булып калу ул — яхшы кеше булып калу, нинди шартларда да әдәп, әхлакны саклау, иманны җуймау, кешелек дәрәҗәсен төшермәү, кылган гамәлләрең белән хайван өммәтенә күчмәү... Кеше булып калу ул — башкаларга авырлык китермәү, кешене сатмау, кулыңнан килгәнчә ярдәм итү. Баһадурны тыңлагач, Гөлҗиһан шуны да аңлады: кеше булып калу ул, иң беренче чиратта, Аллаһ кушканча яшәү икән. Аллаһның ризалыгын алу. Сүзең белән генә түгел, гамәлләрең белән дә. Баһадур, бала гына булса да, иң кирәген аңлап алган. Ул, чын мәгънәсендә әүлия, хикмәт иясе иде шул. Аллаһның ризалыгын алу өчен намаз укырга кирәклеген ул тиз аңлаган. Башкаларны да шуңа өндәгән, шул үрнәкне күрсәткән. Димәк, намазсыз гына, фарыз гамәлләрне үтәмичә генә кеше булып калып булмый икән. Аллаһның ризалыгын алып булмый икән, чөнки Ул бу эшләрне адәм баласына үтәргә боерган. Димәк, Гөлҗиһанга да бу хакта бик җитди уйларга һәм гамәленә керешергә кирәк!.. Һәм балаларын да шул юлга өндәргә. Аларның барысына да Баһадур үрнәк булып тора, ә аның яшәү рәвеше бөтенләй башкача иде.

Һәм үлгәненнән соң беренче тапкыр Гөлҗиһан Баһадурны төшендә күрде.

Улының кечкенә чагы икән.

Ул Караболак болынында билдән чәчәк арасында утыра.

Ул чәчәкләр шулхәтле матур, шулхәтле җете төстә — Гөлҗиһанның әле беркайчан да андыйларны күргәне юк иде. Болын өстендәге көмеш нурдан күзләр камаша, Гөлҗиһанның, күк капусы ачылганда гына, мондый нурны күргәне булды. Бу болында Баһадурга күбәләк кебек фәрештәләр хезмәт күрсәтә, алар әле малайны, канатларына утыртып, болын өстеннән очыртып йөртәләр, әле бишектә тибрәткәндәй назлап йоклаталар. Гөлҗиһан моңа кадәр күрмәгән әллә нинди кошлар Баһадурның баш очында сайрап тора. Бала, нәни кулларын сузып, болынның аргы башыннан кемнедер чакыра, кемнедер көтә. Болынның ул башы караңгырак, анда төркем-төркем кешеләр басып торганы күренә. Чү, Гөлҗиһан үзе дә алар арасында түгелме соң? Фәргать тә анда бит, игезәкләр дә. Нигә алар Баһадур белән бергә түгел соң? Гөлҗи-

һан төшендә улы янына йөгереп бармакчы була, әмма ике арада кылдан нечкә, кылычтан үткен тар күпер күреп, артка чигенә. Күпернең астында — утлары ургып торган тирән чокыр, күпергә кергән кешеләрнең күбесе анда тәгәрәп төшеп китә. Гөлҗиһан анда керергә курка, керсә, ул да аска төшеп китәр кебек. Кермәсә, улы янына чыга алмый, ике арада утлы җәһәннәм. Халык төркеме аны арттан алга таба этә, кире чигенер урын юк. Теге якта, нурлы болында, кулларын сузып, аңа таба улы йөгерә. Гөлҗиһан, тәвәккәлләп, сират күперенә керә. Артта — халык, аста — упкын, алда улы көтә. Менә ул беренче адымын ясый, менә икенчесен... Тирә-як дөм караңгы, бары тик үзеннән төшкән нур гына аяк астын яктырта. Әмма ул нур бик зәгыйфь, Баһадурныкы кебек, бөтен тирә-якны яктыртмый, Гөлҗиһанның үзенә дә җитми. Яктылык, нур эзләп, Гөлҗиһан тилмереп тирә-ягына карый, әмма башкаларның хәле үзенекеннән дә яман икәнлеген күрә. Кешеләр дөм караңгыда сират күперен кичмәкче булалар һәм берәм-берәм аска тәгәриләр. Барысы да аның танышлары. Моны күреп, Гөлҗиһан куркуыннан кычкырып җибәрә һәм сискәнеп күзләрен ача.

Юк, ул җәһәннәм чокырында түгел, үз өендә ята.

Ул сират күперенең нәкъ уртасында уянып китте.

Алга бара алмыйча уянды.

Аңа яктылык җитмәде.

Аста — утлы җәһәннәм, каршыда — нурлы болын, җәннәт бакчасы иде. Ә анда — улы Баһадур. Гөлҗиһанның башына килгән беренче уй улы турында булды. «Улым җәннәттә икән! — дип сөенеп уйлады ул. — Аңа җәннәт кошлары хезмәт итә, фәрештәләр хөрмәт күрсәтә...» Үзенең караңгыда, утлы җәһәннәм өстенә эленгән тар күпердә басып торуын күз алдына китерде. Әйе, ул күпергә керде. Әмма аннан соң нәрсә булды? Үтә алдымы бу утлы күперне Гөлҗиһан? Әллә, башкалар кебек, җәһәннәм чокырына тәгәрәп төштеме? Бәлки, улы янына, нурлы аланга чыгып җитә алгандыр ул? Бәлки, ярдәм көтеп, күпер уртасында басып калгандыр? Аңа бит нур җитмәде, яктылык җитмәде. Таһирҗан бабай, кешенең бу дөньяда эшләгән яхшылыклары, кылган фарыз гамәлләре, сират күперен үткәндә, барасы юлын яктыртыр, дип сөйли иде. Димәк, Гөлҗиһанга бу күперне үтү өчен гамәл җитми. Аллаһ кушканча яшәү җитми...

Бу төштән соң Гөлҗиһан бик нык уйга калды. Димәк, ахирәт көнендә бу утлы күперне кичү өчен яхшы булу гына җитми икән. Ул Таһирҗан бабайның «намаз кирәк, кызым, даими намаз кирәк... Үлгәч беренче соралган нәрсә намаз булачак» дигән сүзләрен исенә төшерде. Гөлҗиһан намаз укый, әмма даими түгел, җае чыкканда яки үзенә кирәк чакта

гына. Таһирҗан бабай кебек, бер дә калдырмыйча көненә биш вакыт намаз укыганы юк Гөлҗиһанның. Төшендә сират күперен кичкәндә, шул нур җитмәде Гөлҗиһанга, намазлары җитмәде. Таһирҗан бабай әйтә иде бит: «Дөньяда кылган яхшылыклар дөньяда кала, намаз ахирәткә бара», —дип. Намазсыз кеше җәннәткә керми икән, яхшылыгы дөнья кадәр булса да.

Гөлҗиһанның күзеннән пәрдә төшкән кебек булды.

Ничек моңа кадәр башына, күңеленә килмәгән соң ул аның? Нигә гел сәбәп тапкан, тарткан-сузган, башка мәшәкатьләргә кереп чумган? Нигә ул беренче урынга Аллаһ кушкан намазларын, гамәлләрен түгел, дөнья кушкан эшләрне куйган? Бәлки, шуңа күрә аның күп эшләре килеп тә чыкмагандыр, бәлки, чыннан да, Аллаһ кушканча яшәмичә бәхетле булып булмыйдыр? Ул үзе генә түгел, ирен, балаларын да шушы юлга тартырга тиеш иде бит. Фәргать инде китте. Сукыр кеше булгач, бәлки, аңа җавап тоту җиңеллек булыр. Туры килгәндә, ул гает намазларын калдырмый иде, Аллаһка ышанды, дөрес яшәде. Аның ире дә, игезәк балалары да гарипләр өммәтеннән, Таһирҗан бабай андыйларны «гозерле» дип атый иде. Ягъни аларның намаз укымаска сәбәпләре бар, әмма укый алсалар, үзләре өчен савап икән.

Менә ул балаларга ничек намаз тәртибен өйрәтергә соң? Телсез-чукрак кешегә ничек Коръән өйрәтергә? Алар бу аятьләрнең гарәпчә әйтелешен бер тапкыр да ишеткәннәре юк бит. Иң яхшысы — аларга кеше белән бергә, имамга оеп уку. Ә теләк-догаларны татарча да кылырга була. Беренче эш итеп, ул балаларына шул догаларны язып бирер, укый, ятлый торсыннар. Ә Караболакка кайткач, Таһирҗан бабайдан әйбәтләп бу турыда сорашырга кирәк. Аларга да инде вакыт җитте, хәтта үтеп бара. Баһадур шушыларны аларның барысыннан да иртәрәк аңлаган булып чыкты. Һәм аларның барысына да туры юлны күрсәтеп китте.

Караболактан алып килгән тартмаларны актарганда, Гөлҗиһанның күзенә пөхтәләп төреп куйган дәфтәр чалынды. Ул шунда ук аны таныды, бу — әнисенең мөнәҗәтләр дәфтәре иде. Гөлҗиһан бала вакытында аны әнисенең кулында еш күрә иде. Караболакта шундый бер йола бар: кеше үлсә дә, туса да, аять ашлары уздыралар. Кеше яңа өйгә күчсә яки нәзер әйткән булса да, халыкны җыеп, Коръән укыталар. Бу мәҗлесләр ирләр-хатыннарның аерым була. Гөлҗиһанның әби-бабалары да, әти-әниләре дә бу аять ашларына күп йөрделәр, үзләренә дә еш чакыралар иде. Кечкенә вакытында Гөлҗиһан картнәенә ияреп тә, әнисе белән дә бу мәҗлесләргә йөрергә ярата иде. Ул әнисенең бик моңлы тавыш белән мөнәҗәт әйткәнен ярата иде, ул җырлаганда, чаршау артына

качып елый иде Гөлҗиһан. Ул әнисен нигәдер бик кызгана иде, аның үлүеннән бик курка иде. Менә инде әнисе дә юк, өч хәсрәт, берьюлы килгәч, берсен-берсе басты. Гөлҗиһан кайсы өчен елаганын, кайгырганын да белмәде...

Мөнәҗәт дәфтәре өстенә Гөлҗиһанның күз яшьләре тамды...

Авылда, нинди авыр шартларда яшәп тә, бер тапкыр намазын калдырмаган, уразасын ташламаган әнисе аңа дөньяның иң изге кешесе булып тоелды. Дөнья мәшәкатенә бирелеп, Гөлҗиһан аңа да вакытын аз бирде кебек. Ә әнисе аларга барысын да бирде — вакытын да, сәламәтлеген дә, бөтен гомерен дә. Инде урыны җәннәттә булсын, Гөлҗиһанның укыган догалары аның рухын шат кылсын...

Гөлҗиһан, Иртәштәге авылдашларын җыеп, үзе дә аять ашы уздырып алырга булды. Өч мәетнең рухы өчен Коръән укытырга ниятләде ул. Аларның да рухлары шатлансын, Гөлҗиһанның да җаны тынычлансын. Чөнки ул бу көннәрдә бик күп кичерде, үзе дә яшәү белән үлем арасында булды, үлеп терелде, яңадан туды. Һәм бу яңа тормышны, калган тормышны Коръән белән башларга кирәк иде...

Игезәкләрнең үз янында ялда булуына да Гөлҗиһан бик сөенде, күрсеннәр халыкның дини һәм милли йолаларын, аралашсыннар. Коръән моңын ишетмәсәләр дә, йөрәкләре, рухлары белән тойсыннар... Кызы Гадилә йорт эшләренә дә бик булган, ризыкны аннан да оста әзерләүче юк. Ул барында Гөлҗиһанга табын өчен борчылырга кирәкми. Гадел исә көннәр буе Баһадурның бүлмәсендә утыра, ул анда үзе өчен яңа дөнья ачты, ахрысы. Ул да хәзер, энесе кебек, компьютер аша бөтен дөнья белән аралаша, телләр өйрәнә, күп укый. Инде японнар белән дә элемтәгә кергән, алар Гаделне бик нык үзләренә чакыралар. Карт япон галиме ислам диненә күчкән, аларның хәзер Япониядә үз мөселман җәмгыятьләре бар икән. Мөслим, Караболактан киткән татар балалары белән хәзер бергәләп намазлар укыйлар икән, Гаделне дә бик чакыралар. Шуңа күрә Гадел хәзер көннәрен инглиз-япон телләрен өйрәнеп уздыра, сөйләшә белмәсә дә, алар белән язып аралаша. Балаларының һөнәрле һәм тырыш булуларына Гөлҗиһан куанып бетә алмый, гарип дип, бер дә күңел төшереп утырмыйлар алар. Хәер, әтиләре дөм сукыр килеш тә дөнья алып барды бит, кеше кулына карап ятмады. Караболак халкы, гомумән, булдыклы, миһербанлы халык, Гөлҗиһанның балалары да шул токымнан бит. Инде Гөлҗиһан үзе исән вакытта аларны башлы-күзле итә алса, күңеле тынычланыр иде. Һәм бу балалары да, Баһадур кебек, Аллаһ юлына кереп китсәләр, Гөлҗиһанга да тынычлап бу дөньядан китәргә була. Ул бу дөньяда үзенең вазифасын үтәгән була.

Алдагы бер ялда Гөлҗиһан Караболак хатыннарын үзенә аять ашына җыеп алды. Иртәшнең теге башыннан зурлап Таифәттәйне барып алдылар, Сөнкүлдән Җәүһәрия түтине чакырдылар. Өй эче ак яулыклы татар хатыннары белән тулды. Нәкъ Караболактагы кебек, нәкъ аларның картнәйләре, нәнәйләре кебек иде алар. Аларны күргәч, Гөлҗиһанның күзләренә яшь бәреп чыкты. «Инде без дә аять ашларына йөрерлек чорга кергәнбез икән бит, — дип уйлады ул, Караболак хатыннарына карап. — Бу изге йолалар, бу аять ашлары бездән соң кемгә калыр, бу татарча моңлы мөнәҗәтләрне бездән соң кемнәр әйтер икән?»

Коръәнне Гөлҗиһанның соңгы классташы Рабига укыды.

Ул авылдан иртә чыгып китте, иртә кияүгә чыкты, калган гомерен гаиләсе белән Иртәштә уздырды. Аның күптән инде ире дә үлде, балалары да Чиләбедә яши, үзе дә хәзер күп гомерен шулар янында уздыра. Рабига яман шеш белән бик иртә инвалидлыкка чыкты, аның да эчендә кисмәгән, ямамаган җире юк, әмма Аллаһның рәхмәте белән, һаман йөреп тора. Кышларын ул балалары янында Чиләбедә яши, шунда мәчеткә йөреп, Коръән укырга өйрәнгән, биш вакыт намазын калдырмый, ихластан шушы юлга кереп киткән булып чыкты. Аның моңлы тавыш белән Коръән укуын барысы да елап тыңладылар. Соңыннан исә Рабига укыганнарының татарча мәгънәсен дә аңлатты, авылдашларын ихлас күңелдән дин-ислам юлына чакырды. Аннан Караболак гадәте буенча сәдака өләштеләр, дога кылдылар, әрвахларны искә алдылар. Барысы да кешечә булды, барысы да Караболакта картнәйләре эшләгәнчә булды. Аннан инде чират табынга җитте, өстәлгә берәм-берәм Гадилә әзерләгән сый-нигъмәт чыкты. Кунаклар ризыкны зурлап, рәхмәтләр әйтеп ашадылар, барысы да элеккеге Караболак тәртибе буенча барды. Ниһаять, чират мөнәҗәтләргә дә җитте.

Авылда аның әнисе башлап мөнәҗәт әйтә иде, шул гадәт буенча, бу юлы да Гөлҗиһаннан башладылар. Ул, бераз каушап, әнисенең дәфтәрен кулына алды, чөнки аның гомерендә беренче тапкыр мөнәҗәт әйтүе иде. Ул тамагын кырып куйды һәм әнисеннән ишетеп калган моң белән мөнәҗәт әйтә башлады. Һәм сискәнеп китте, чөнки ул әнисе тавышы белән мөнәҗәт әйтә иде. Әйтерсең лә аять ашына әнисе үзе кайткан һәм моңлы тавыш белән җырлый иде:

Атамның бер гөле идем,
Анамның былбылы идем.
Бу хәсрәткә гаҗиз булдым,
Сабыр бирсен үзе Алла.

И, туганнар, беләсезме,
Минем хәлнең авырлыгын.
Пәйгамбәрләр сабыр иткән,
Сабыр итеп, әҗер алган.

Чиксез димә гомереңне,
Якын дип бел үлемеңне.
Сәхәрләрдә зекер әйтеп,
Чыныктыр син күңелеңне.

Сабыр итик, сабыр итик,
Сабыр коллар сабыр итә.
Сабыр коллар сират күперен
Искән җилләр кебек үтәр.

Сабыр итик, сабыр итик,
Сабыр колдан шайтан качар.
Сабыр коллар җәннәт ишеген
Үз куллары белән ачар.

Мөнәҗәтләрем һич бетмәс,
Кәгазь белән каләм җитмәс.
Йөрәгемдин кайгы китмәс,
Рәхимең кыйл, Рәсүлуллаһ.

Гөлҗиһан үзе җырлый, үзе елый. Бите буйлап кайнар күз яшьләре тәгәрәп төшәләр дә дәфтәр өстенә тамалар. Гөлҗиһан белән бергә, дәфтәр битендәге сүзләр дә елый. Караболак хатыннарын да әллә нинди тирән моң-сагыш сарган, алар шушы мөнәҗәтне әйтеп утырган әниләрен, карт әбиләрен күз алларына китерәләр. Ак яулыклар ябынган йөз яшьлек татар карчыклары иде алар. Караболакның тел, моң һәм иман сагында торучылар. Авылның иң яхшы гадәтләрен, сыйфатларын, мөнәҗәт-догаларын буыннан буынга тапшырып калучылар. Алар юк инде. Әмма алардан калган мөнәҗәтләрне, гореф-гадәтләрне Гөлҗиһаннар буыны саклый. Гөлҗиһаннардан соң болар барысы кемгә кала? Бу хатыннарның күбесе авыру, гарип, кайсының бөтенләй баласы юк, булганнарыныкы чирле. Шәһәрдә генә түгел, хәтта авылда да урысча укыта башладылар, балалар ана телләрен белмиләр, мөнәҗәтнең нәрсә икәнен аңламыйлар.

Гөлҗиһаннан соң Караболак хатыннары барысы да берәм-берәм мөнәҗәт әйтеп чыктылар. Барысы да белә, хәтерле икән. Алар әйтерсең лә мөнәҗәт әйтмиләр, Караболак тарихын язалар, үзләренең ачы язмышларын сөйлиләр...

Хәсрәт хәсрәткә охшамый,
Хәсрәт урыны бушамый.
Һәркемгә дә бер хәсерәт,
Минем хәсрәткә охшамый.

Йөрәкләрне утлар алган,
Бәгырьләрне шулар ярган.
Бу хәсрәтнең ачылары
Рәсүлуллаһыбыздан калган.

Хак Тәгалә хәзрәтенә
Үз рәхмәткәйләрен биргәй.
Һәр адәмнең язмышында
Ходайның тәкъдире бар кый...

Мөнәҗәтләр беткәч тә, бертын Караболакны, әни-әбиләрен искә төшереп утырдылар. Тагы бер тапкыр чәй эчеп, ашка дога кылгач, авыл хәлләрен сөйләшеп алдылар, тагы хатирәләргә биреләделәр. Гөлҗиһаннар классында укыган егерме тугыз баланың инде егермедән артыгы юк икән, шуларның барысын да искә төшереп чыктылар. Кайсы яман шештән үлгән, кайсы — кан, шикәр чиреннән. Кайсы, үләлмичә тилмереп, урын өстендә ята, кайсының баласы чирле яки тиле. Кем язмышына килеп кагылсаң да, кан саркып тора. Гөлҗиһан өченче класста төшкән бер фотосурәтне алып килде, аны күреп, тагы аһ иттеләр, тагы бер елап алдылар. Рәсемнән, томырылып, шаян, тере авыл балалары карап тора иде. Алар алда үзләрен нәрсә көткәнне белмиләр шул әле.

— Менә Мәйсәрә Салихова, хәтерләсәгез, укыганда нинди ябык, зифа кыз иде. Бөтенләй җәелеп, шешенеп, шикәр чиреннән үлде, бөере, йөрәге бөтенләй чәрдәкләнеп беткән булган мескеннең. Ике ятим баласы калды, — диде Гөлҗиһан, рәсемне кулына алып.

— Ә менә монысы Саҗидә, үпкә рагыннан үлде, Мәрзия ашказаны рагыннан китте, Гайсин Әгъзам дә рактан үлде, — дип дәвам итте Рабига.

— Аның янында утырган Дәүләтшина Мәрьям үпкә рагыннан үлде, Нигъмәтуллин Нургали рактан үлде. Хәлилне, йөрәктән үлде, диделәр. Мөхәммәтшин Хәлим бөер рагыннан үлде, Тайрәнең баласы булмады, ул да үлде. Аның уң ягында Гөлфирә утыра, ул да үлде. Менә тагы бер Гөлфирә — Нигъмәтуллина, ул операция өстәлендә үлде, шикәр чире булган, бөерләре эшләүдән туктаган. Кинҗәбаева Гөлфирә дә рактан үлде, Зарипова Асия дә шуның белән китте. Менә бу Барис исемле малай, фамилиясен оныттым, ул да үлде, рактан. Рифкать тә рактан китте. Габбасова Мәрьям, хәтерлисездер, аның, җиденче класста укыганда, бөтен чәче коелган иде, ул да үлгән инде. Мөхәммәтшин Рифкать яшьтән үк рактан үлде. Кинҗәбаев Сәгыйть — анда бөтен авырулар бар иде, рактан кибеп үлде. Менә бу Җәләлетдинов дигән малайны, кара чутыр булгач, негр дип йөртә идек, нигәдер, елка дип үрти идек. Аны да үлгән дип ишеттем. Шарван үлде. Рәшидә үлде. Без бередә икәү генә исән калдык...

Шулай санап чыктылар да сүзсез калдылар...

Әйтерсең лә авыл өстеннән, аларның балачаклары өстеннән атом сугышы үткән иде. Беркем калмаган. Югыйсә аларга алтмыш яшь тә юк бит әле. Укытучыларның да берсе-бер калмаган. Иң беренче алар киткән. Алардан бары тик хатирәләр дә шушы рәсемнәр генә калган...

Аннан суд эшләре турында да сөйләшеп алдылар. Фәргать исән вакытта, алар суд юлында күп йөрделәр, әмма аларны бөтен җирдән кире бордылар. Алар бер җирдә дә үзләрен «Маяк» шартлаудан зарар күргән булуларын исбатлый алмадылар...

— Син авырып ятканда, Чиләбе судыннан отказ килде, Мәскәүгә биреп тә тормадык инде, — диделәр Караболак хатыннары. — Барыбер ярдәм итмәячәкләр, йөрәк бозып йөрү генә. Шуңа күрә без туктадык.

Гөлҗиһан үзенең «Маяк»ны яңадан судка бирүен әйтте. Әмма Караболак хатыннары аны яптыруга ышанмадылар, чөнки бөтен шәһәр «Маяк»ка карап тора иде. Аларның үзләренең дә гаиләләре атом комбинаты белән бәйләнгән, бөтен килерләре шуннан. Бу мәсьәләдә алар Гөлҗиһанга ярдәмче түгелләр иде...

Хатыннар таралгач, Гөлҗиһан классташы Рабигадан беразга калуын үтенде. Аның Рабигадан аз булса да дин тәртибен өйрәнәсе килә иде. Рабига моңа бик сөенеп риза булды, башта Гөлҗиһанның үзеннәнниләр белүен сорашты. Аның гаҗәпләнүенә, Гөлҗиһан намаз-тәһарәт тәртибен дә, аять-догаларны да яхшы белә иде.

— Соң, син үзең дә барысын да беләсең икән бит, Гөлҗиһан! — диде ул сөенеп. — Намаз укыйсы гына калган бит.

— Намазын да анда-санда кешегә ияреп укыйм инде мин аның, — диде Гөлҗиһан. — Синнән дөреслеген тикшертәсем килгән иде, чөнки үзем генә тәвәккәлләп укыганым юк. Гел дөнья йотты, тулысынча белмим, башласам, тота алмам дип тә уйладым. Бер-бер артлы өч мәет озаткач, дертләп уянып киткән кебек булдым. Намазсыз яшәргә ярамый икән бит, Рабига. Намазсыз бәхетле булып булмый икән, җәннәтле булып булмый икән. Гомер буе Аллаһтан бәхет сорадык, ә үзебез ул сораганны үтәмәдек. Мин моны соң булса да аңладым...

— Әле соң түгел, Гөлҗиһан, соң түгел. Күзләрең йомылганчы, беркайчан да соң түгел. Моны аңламаучылар да бик күп бит әле. Син аңлагансың, рәхмәт. Сезнең нәсел барысы да дини иде шул, бер Таһирҗан бабай гына да ни тора. Улың Баһадур турында бөтен авыл таң калып сөйли — үләр алдыннан бөтен Караболакны җыеп намаз укыткан бит ул бала. Хәзер дә елый-елый шул хакта сөйлиләр, аның клубта әйткән сүзләрен искә төшерәләр.

Баһадурны, Фәргатьне, Гөлҗиһанның әнисен искә төшереп, тагы бер елашып алдылар. Гөлҗиһан Рабигага Рәшидәнең үзе чыгарып калдырган бәетен дә күрсәтеп алды.

— Бу хәлләр булмаса, Рәшидә укыган булыр иде, бәлки, китаплар язар иде, — диде Рабига, аның бәетен укып. — Күпме талантлы кешеләр харап булды Караболакта. Бөтен тирә-якта...

Алар рухы өчен бергәләп дога кылдылар.

Аннан бергәләп икенде намазы укыдылар.

— Аллаһ синнән риза булсын дисәң, беркайчан да намазыңны калдырма, — диде Рабига Гөлҗиһанга китәр алдыннан. — Мөселман өчен иң зур кайгы — намаз калдыру. Аллаһ каршында иң изге гамәл — даими укыган намаз. Ашавың калса да, намазың калмасын, чөнки намаз — җан азыгы, ә ризык — тән азыгы гына.

Рабига Иртәштә вакытта, Гөлҗиһаннарга килеп, бераз дәрес тә бирергә булды. Монысына Гөлҗиһан бигрәк тә сөенде, аның Коръәнне үз куллары белән тотып, үзе аңлап укыйсы килә иде. Карттай-картнәйләре кебек, Таһирҗан бабай кебек, улы Баһадур төсле. Һәм Гөлҗиһан моңа өлгерергә тиеш иде.

## Унҗиденче бүлек

Игезәкләр ялда вакытта Гөлҗиһан алар белән тагы бер тапкыр Караболакка кайтып килергә булды. Кышларга кергәнче, Таһирҗан бабайны да күрәсе килде, нигәдер күңеле дә шулай кушты. Йөрәге юкка гына шулай дулкынланмаган икән, кызының язмышы хәл ителәсе булган авылда, шуңа күрә Гөлҗиһан алар белән Караболакка ашкынган.

Игезәкләр, авылга кайту белән, Таһирҗан бабайларга чыгып киттеләр. Чөнки теге кайтканда алар чечен гаиләсе белән бик дуслашып калганнар иде. Үзләрен дә, балаларын да бик яраттылар, Иртәштән алар өчен дөнья кадәр бүләк тә төяп кайттылар. Гөлҗиһан өйдә бераз җыештырынып калды, игезәкләр бүләкләрен алып чыгып та киттеләр. Анда исә Гадиләне тәкъдире көтеп тора иде.

Бу юлы Таһирҗан бабайларның өйләре тулы кунак иде.

Чечен гаиләсе янына, аларның монда икәнлекләрен ишетеп, таныш гарәпләре килгән булып чыкты. Мәккәнең үзеннән килгән бу гарәпләргә Таһирҗан бабай да, Караболак халкы да могҗизага карагандай карадылар. Коръән һәм пәйгамбәр телендә сөйләшкән бу кешеләр аларга изге булып күренде. Сәит Абдрәхим исемле кара-кучкыл бер гарәп егетен хәтта Мөхәммәт пәйгамбәр нәселеннән, диделәр. Моны-

сына инде халык бөтенләй аһ итте, Караболакка Мәккәнең үзеннән Мөхәммәт пәйгамбәр варисы килер дип, алар гомерләрендә дә уйламадылар. Дөрес, Караболакка кемнәр генә килмәде — немецы да, японы, инглизе дә, шведы, французы да, тагы әллә кемнәр. Ә менә гарәпләрнең килгәне юк иде. Чечен гаиләсе шушы могҗизага сәбәпче булды.

Караболак халкы Мәккә гарәпләренә карап шаккатса, гарәпләр аларга карап гаҗәпләнделәр. Иң беренче булып, алар Таһирҗан картка карап аптыраштылар. Чәчләре, сакалы яңадан карала башлаган, йөзе балаларныкы кебек шоп-шома булып калган бу картка йөз яшь икәнлеген белгәч, алар таң калдылар. Чечен ире гарәпчә шактый яхшы белә булып чыкты, ул аларга Таһирҗан бабай турында да, Караболак хакында да җентекләп сөйләп бирде. Мондагы хәлләрне белгәч, халыкның меңәрләп радиациядән кырылуы турында ишеткәч, гарәпләр телсез калдылар. Аннан, Коръәнгә нигезләп: «Мондый урыннан китү, һиҗрәт кылу тиеш», — диделәр. Әмма авылда китәрлек халык калмаган иде инде — балалар юк, картлар үлем көтеп ята икән. Гарәпләр авыл халкын бик кызгандылар, аңа ничек ярдәм итү турында уйлый башладылар. Теләге булган кешеләрне, бигрәк тә яшьләрне, үз илләренә алып китәргә кирәк дигән фикергә килделәр, шул хакта халыкка да җиткерделәр.

— Олы як беркая да кузгалмаячак инде, — дип җавап бирде моңа каршы Таһирҗан карт. — Японнар да чакырып караган иде, картлардан беркем китәргә риза булмады. Менә балаларны, яшьләрне алып китә алсагыз, яхшы булыр иде. Изге җирләрдә иманнарын саклап калырлар иде...

Шулай килештеләр — теләүчеләр балаларын гарәпләр белән җибәрә ала иде. Бу эш белән өлкәнең башка татар авылларында да шөгыльләнергә булдылар. Шулай сөйләшеп утырганда, Таһирҗан бабайларга Гадел белән Гадилә килеп керде. Өйдә чит кешеләрне күргәч, алар уңайсызланып куйдылар, Гадилә чаршау артына ук кереп качты. Чеченнарның кечкенә балалары йөгереп килеп, аны олы якка өстерәп карасалар да, Гадилә анда чыкмады. Ул арада бабасы килеп, аңа яулык бөркәтте, оныгын җитәкләп олы якка алып чыкты.

— Бу минем оныкларым була — Гадел-Гадилә, — дип таныштырды аларны Таһирҗан карт. — Әти-әниләре шушы авылдан, әтиләре вафат инде. Үзләре шул атом бомбасы ясый торган шәһәрдә туып үстеләр. Хәзер Чиләбедә яшиләр, үзләренең гаиләләре юк әле.

Гадилә килгән кунаклар арасында кара-кучкыл гарәп егетен дә шәйләде, ул да, күз сирпеп кенә, берничә тапкыр Гадиләгә карап алды. Бу кыз бала күз явын алырлык гүзәл иде. Аның йөзе ак, нурлы, сызылып киткән кара кашлары астыннан

зур яшькелт күзләре карап тора. Кызның йөзе вакыт-вакыт алланып китә, озын кара керфекләре тетрәп куя, гүя ул дөньяны җаны белән тыңлый, җаны белән ишетә. Аның телсез-чукрак икәнлеген дә белгәч, гарәп егетенең күңеле мәрхәмәт хисләре белән тулды. Егетнең бу карашыннан Гадиләнең битләренә тагы ут капты, оялып, ул тизрәк икенче якка чыгып китте.

Кичке якта Гөлҗиһан бу кадерле кунакларны үзләренә чәйгә дәште...

Караболакта гадәт шундый иде: берәрсенә кунак килсә, аны барысы да үзенә алдырырга, сыйларга тырыша. Гомер буе, хәтта иң авыр елларда да шулай булган, халык бу гадәтен тотарга тырыша. Кешеләргә бигрәк тә мосафирның догасы кадерле. Гөлҗиһан белән Гадилә дә көне буе өйне җыйдылар, табын тутырып милли ризыклар әзерләделәр, кадерле кунакларның күңелләрен күрергә тырыштылар. Гадилә, күбәләк кебек, ике якта бөтерелде, әйтерсең лә ул атлап түгел, очып йөри. Әйтерсең лә аның иңнәренә пар канатлар үскән иде. Ул ризыкны да үзе пешерде, табынны да үзе әзерләде, кунакларны да үзе сыйлады. Аның алсуланып янган битләре, вакыт-вакыт калтырап киткән ак нәфис куллары гына дулкынлануын сиздерә иде. Аңа карап, Гөлҗиһан үзенең яшьлеген искә төшерде. Фәргать белән очрашканда, ул да шулай янган, дулкынланган иде бит. Хәтта чаршау артында елап та алган иде. Кызына шул арада нәрсә булган соң, кем аны шулай бер агарырга, бер кызарырга мәҗбүр итә?

Шулчак Гөлҗиһанның күзе өстәл артында бер агарып, бер кызарып утырган гарәп егетенә төште. Ул, Гадилә күтәрелеп караган саен, кызарып-янып чыга иде. Ана кеше күреп алды: кайвакытта яшьләрнең карашлары да очраша, һәм алар бер-берләреннән күзләрен ала алмыйлар иде. Күренеп тора, алар бер-берләрен ошаталар... Бу уйдан Гөлҗиһанның башлары әйләнеп китте, мөмкин хәлме — Мөхәммәт пәйгамбәр нәселеннән булган сәит килеп, әллә кайдагы бер татар авылындагы кыз балага гашыйк була? Һәм ул кыз — аның баласы Гадилә... Бу мөмкин хәлме? Телсез-чукрак булу сәбәпле, ул бит инде ничә еллар үз тиңен таба алмый, инде яшьлеге дә үтеп бара иде. Бәлки, Аллаһы Тәгалә аны нәкъ менә шушы очрашу өчен саклагандыр, аның тәкъдире, бәлки, шушы егеттер?

Гөлҗиһанның уйлаганнары дөрес булып чыкты — Абдрәхимнең Гадиләгә күңеле төшкән һәм ул аның туганнарыннан кызны сорарга җыена иде. Бу тәкъдимнән Гөлҗиһан Гадиләгә караганда да ныграк дулкынланды, бер улына, бер Таһирҗан бабайга карады. Гадилә исә, уңайсызланып, чаршау артына ук кереп качты. Гадел аның янына кереп, хәлне аңлатты, игезәк туганын җитәкләп, олы якка алып чыкты.

Гадилә, зур яшел күзләрен тутырып, гарәп егетенә күтәрелеп карады. Аларда каушау да, өмет тә, сагыну-сагыш та, олы рәхмәт хисләре дә чагыла иде. Гомер буе тилмереп көткән кешесенең шушы гарәп егете икәнлеген аңлады Гадилә. Аны бер күрүдә аңлады. Егет тә аны аңлаган, алар телсез-сүзсез, йөрәкләре, җаннары белән аңлашканнар, бер-берләрен табышканнар. Аның тәкъдименә Гадилә озын керфекләрен тибрәтеп җавап бирде, кызарып янган иреннәре сүзсез генә ризалыгы турында хәбәр итте. Бу хәбәрне әнисе шунда ук аңлап алды. Хәзер аның үзенә бер фикергә килергә кирәк иде.

Шушы мизгелләрдә Гөлҗиһанның күз алдыннан кызының бөтен гомере үтеп киткән кебек булды. Интернат-мәктәпләрдә, тулай торакларда үткән тавышсыз-телсез гомер. Күмәк ашау, күмәк яшәү, күмәк эшләү. Һәм гомер буе үзеңне мәңгегә чорнап алган тавышсыз дөнья. Гомерлек ялгызлык. Ата-ана назы гына тутыра алдымы икән бу тавышсыз-телсез бушлыкны? Бәхетле булдымы икән кызы Гадилә ул Чиләбенең җимерек тулай торакларында? Алга таба аны бирәдә нәрсә көтә? Гөлҗиһан — авыру, аның көннәре санаулы. Әтисе юк. Игезәк туганы да үзе кебек инвалидлар тулай торагында көн күрә. Иртәштә яшәү сәламәтлек өчен тагы да куркыныч. Кызының инде яшьлеге үтеп бара, әмма аның әле мәхәббәте булганы юк, ул гел ялгыз. Бәлки, бу гарәп егете аның бәхетедер? Язмышыдыр? Үзләре риза икән, үзләре бер-берсен ошатышканнар икән, нигә Гөлҗиһан каршы булырга тиеш әле? Шулаен ул шулай да, ә ничек биреп җибәрергә аны беренче тапкыр күргән кешегә?

Гөлҗиһанның югалып калуын, уйга батуын күреп, Таһирҗан бабай да үз сүзен әйтүне кирәк тапты:

— Ризалашырга кирәктер, кызым, — диде ул, ныклы итеп. — Мөселманнар бит алар. Мин егетне ничә көн күзәтәм, гаять тәкъва адәм. Бик гыйлемле, бөтен Коръәнне яттан белә. Ул әдәп-әхлагын инде әйтәсе дә юк, бездә хәзер андый кешеләр юк инде. Яшьләр үзләре дә бер-берләрен ошаткан булырга тиеш, шулай күренә. Мондый кеше янында Гадиләнең үзенә дә тыныч булыр, янында яклаучысы-саклаучысы булыр. Иншаллаһ, дин юлына да аяк басар...

— Бигрәк еракка җибәрәсе бит, Таһирҗан бабай. Берүзе нишләр ул анда?

— Ул анда берүзе булмый инде, ире белән була, кызым, — диде Таһирҗан бабай. — Аның анда туганнары бик күп икән, бик хәлле, укыган кешеләр, ди. Бу илнең киләчәге юк, кызым, монда ябышып ятарга ярамый хәзер. Бигрәк тә яшьләргә, бигрәк тә мөселманнарга. Үз тиңнәреңянына китәргә кирәк. Яшь чагым булса, ике дә уйламас идем, үзем дә китәр идем әле. Хәзер соң шул инде, соң...

Гөлҗиһан хәрәкәтләр белән улына да хәлне аңлатып бирде, аның фикерен, ризалыгын сорады. Гадел үзе дә күңеле белән инде барысын да сизенгән иде. Аның җавабы кыска булды: «Гадилә үзе ничек тели, шулай булсын, мин риза», — диде ул, хәрәкәтләр белән аңлатып. Гадилә үзе Мәккә шәһәреннән килгән гарәп егетенә кияүгә чыгарга риза иде.

Шулай итеп, барысы да хәл ителде.

Никахны бүген кич үк укытырга ниятләделәр, чөнки иртәгә гарәпләргә Чиләбегә китәргә кирәк иде. Ул арада күрше-күлән чакырылды, хатын-кызлар яңа табын әзерли башладылар. Ирләр, ахшам намазы укып алганнан соң, эшкә керештеләр. Иң олы туганы буларак, Гадилә белән Абдрәхимгә никахны Таһирҗан бабай укыды. Гөлҗиһанның күз алдына тагы үз никахы килде, янында Фәргате утырган кебек булды. Исән булса, кызы өчен сөенер иде ул, динле, иманлы кеше белән тормыш корганына куаныр иде. Таһирҗан бабай дөрес әйтә — бу илнең киләчәге юк. Моннан мөмкин кадәр ерак качарга, китәргә кирәк. Бу илдә татарларның, мөселманнарның беркайчан кадерләре дә, кирәкләре дә булмады. Шуңа күрә кадереӊ, кирәгеӊ булган җиргә китәргә кирәк...

Никах мәҗлесеннән соң ирләр җыелышып мәчеткә ясту намазына киттеләр.

Имам булып, халык алдына гарәп егете басты. Аның артына Караболак халкы тезелде.

Нух пәйгамбәрдән калган борынгы җирләрдә татары, чечены, гарәбе бергәләп, бер Аллаһка гыйбадәт кылалар иде.

Аларга имам булып Мөхәммәт галәйһиссәламнең нәселен дәвам итүче сәит тора, Караболак халкы аңа оеп намаз укый иде. Бәлки, нәкъ менә шушы мизгел, шушы олы бәхет өчен Аллаһ аларны барлыкка китергәндер, зур сынаулар аша, шушы көнгә хәтле китереп җиткергәндер. Барысы да кала — авырулар да, авыл да, хәтта тормыш үзе дә. Ә менә бу эчкерсез намазлар, бу догалар аларның үзләре белән китәчәк. Утлы сират күперләрен кичкәндә, барыр юлларын нур булып яктырту өчен, җәннәтләргә керү өчен менә шушы намаз-догалары кирәк булачак. Моны хәзер Караболак халкы да аңлый башлаган иде...

Гадилә белән Абдрәхимгә урынны каршыдагы әби-бабайлар йортына әзерләделәр. Гөлҗиһан күрше хатыннар белән аны ягып җылытты, ялт итеп җыештырып чыгарды, чиста урын-җирләр кертеп куйды. Яшьләрнең ашыйсылары-эчәселәре килсә дип, кайнар чәен, камыр ризыкларын, җиләк-җимешен кертеп тутырды. Түр якта, кыйблага каратып, борынгы намазлыкларны җәеп куйды, өстәл өстендә Коръән китабын калдырды. Алай да нәрсәдер җитми кебек тоелды, йөгереп, өйдән чүлмәк-чүлмәк гөлләрне алып кертеп куйды.

Урамда кара күз булса да, алар шау чәчәктә утыралар иде. Бераз уйланып торды да, сандык төбеннән алып, стеналарга чиккән сөлгеләр, чиккән тукымалар элеп куйды. Боларны Гадилә әле бала вакытта ук үзе чиккән иде. Аннан берничә урынга шау чәчәкле чаршаулар тарттырды, тәрәзәләргә ап-ак пәрдәләр элде. Ярулла карт белән Нурҗамал карчыкның иске өе җәннәт почмагына охшап калды. Гөлҗиһан зур җиз комганга җылы су тутырды да, аны мич алдына куеп, әкрен генә өйдән чыгып китте. Аның әнисе дә Фәргать белән икесенә зөфаф төннәрен нәкъ шулай әзерләгән иде.

Икенче көнне Абдрәхимнәр Чиләбегә китеп бардылар.

Алар барысы да уразага Мәккәгә кайтып китәргә җыеналар иде...

Ул арада Гадилә, эшеннән чыгып, тиз арада чит ил паспорты ясатып алды. Җыелышып киңәшкәннән соң, Гадел дә алар белән Мәккәгә китәргә ризалык бирде. Монысына Гөлҗиһан куанды гына, чөнки чит җирләрдә бер тугансыз Гадиләгә барыбер авыр булыр иде. Бигрәк тә телсез-чукрак кешегә. Гадел соңгы вакытта чит телләрне дә шактый гына өйрәнеп алган, язып булса да үзенә ни кирәген аңлата ала иде. Ул Гадиләгә беренче көннәрендә зур ярдәмче, зур терәк булачак...

Кышкы салкыннар башланганчы, алар барысы да җыелып Мәккәгә кайтып та киттеләр. Алар белән бергә Караболактан укырга берничә егет тә китте, күрше авыллардан да татар яшьләре бар, диделәр. Димәк, аның балалары анда ялгыз булмаячак.

Шулай итеп, Урал тауларыннан Мәккәгә сукмак салынды...

Урыс иленнән җәбер-җәфа күргән татарлар, исән калу өчен, дөнья буйлап таралдылар. Һиҗрәткә чыктылар. Кайсы — гарәп илләренә, кем — Япониягә, кем — Төркиягә, Германиягә, кемнәр — ерак Америкага. Берәм-берәм булса да китеп бардылар, берәмләп булса да, бу утлы-бозлы җәһәннәмнән качтылар. Китә алмаганнар, йөри алмаганнар, китәргә теләмәгәннәр атом казаны өстендә утырып калдылар... Инде бу газапларның ахырын көттеләр...

## Унсигезенче бүлек

Ураза керүгә, Иртәштә Гөлҗиһанның суды башланып китте...

Гөлҗиһан аңа яуга хәзерләнгән кебек әзерләнде...

Әмма органнар да моңа бик нык әзерләнгән булып чыктылар.

Уен эшмени — Иртәш тарихында беренче тапкыр «Маяк»ны яптырырга дигән гариза карала бит! Әлбәттә, бу га-

ризаны кабул итмәскә, төрле юллар белән кире борырга, бу эшне карамаска да булыр иде. Әмма халык арасында төрле коткы, сүз күп таралды, хәтта заман ахыры белән куркытучылар да бар. Шәһәр халкы болай да өркеп-куркып беткән, миңгерәйгән, шуның өстенә аларны дөнья бетү белән куркыталар. Шушы коткыны берьюлы бастыру өчен, күргәзмә суд ясау кирәк иде. Коткы таратып йөрүчеләрне дә халык алдында акылга утыртырга кирәк иде.

Һәм органнар да бу судка бик ныклап әзерләнделәр...

Айлар буе газета битләреннән патриотик эчтәлекле язмалар өзелеп тормады. Имеш, «Маяк» илне атом сугышыннан саклап калган икән, «Маяк» бүген дә Россияне бөтен бәлаләрдән саклап тора икән. Имеш, Иртәш илдә иң чиста, иң бай шәһәр икән, башкалар талонга утырганда, монда колбаса ашаганнар, башкалар бушка эшләп йөргәндә, монда уч тутырып акча алалар. Ләкин кемнәргәдер бу ошамый икән, алар, чит илләрнең котыртуы сәбәпле, «Маяк»ны бетерергә йөриләр, ди. Бу кешеләрнең балалары гарәп илләрендә ваххабилыкка өйрәнеп яталар икән, монда кайтып та әлләниләр китереп чыгарырга мөмкиннәр, ди. Урыс газеталары айлар буе менә шул хакта язды, радиолар шуны сөйләде, Чиләбе һәм Иртәш телевидениеләре «Маяк»ка дан җырлады.

Менә шундый шартларда суд эшләре башланып китте...

Гөлҗиһан бу судка берьялгызы килде. Чөнки авылдашларының кайсылары инде үлеп беткән, кайсылары уразага авылга кайтып киткән, кышка балалары янына күчкән иде. Бу гаугалы эштән куркып калучылар да булгандыр, чөнки соңгы вакытта газета битләрендә Иртәштә яшәүче татарлар исеменә төрле сүзләр ишетелә башлады. Имеш, аларга гына нидер җитми, алар гына бутый, алар гына судлаша. Татарларның биредә хәтта мәет күмәргә зиратлары да булмавы, шәһәрдә милли мәктәпләре дә, мәчетләре юклыгы турында газеталар язмый. Алар татарларны шәһәрдә милләтара тынычлыкны бозуда гаеплиләр, башкаларны уяу һәм сак булырга чакыралар.

Суд бинасына җитәрәк, Гөлҗиһан аптырап туктап калды. Монда бөтен урам халык белән тулган иде.

Шатлыктан Гөлҗиһанның йөрәге кысылып куйды — ул халык үзен якларга килгән дип уйлады. Әмма якынлашкан саен, аның адымнары акрынайды, күз аллары караңгыланды, тәнен хәлсезлек басты. Гөлҗиһан аларның кулларындагы язуларны күргәч кенә аңлады: шәһәр халкы аңа каршы чыккан иде. «Кто против «Маяк»а — тот против человечества», «Маяк» — ядерный щит страны», «Маяк» — защитник России», «Маяк» и город — неделимы», «Кто против «Маяк»а — езжайте в Монголию» һәм тагы әллә нинди язулар, өндәмә-

ләр, рәсемнәр. Берничә кешенең кулында Гөлҗиһанның да сурәте, аның маңгаена «Предатель» дигән тамга сугылган. Моны күреп, Гөлҗиһанның күз аллары караңгыланып китте. Халык арасында Гөлҗиһанны танучылар да бар булып чыкты, чөнки бу көннәрдә аның рөхсәтеннән башка рәсемен шәһәр телевидениесеннән күп күрсәттеләр, газеталарда бастырып чыгардылар. Бу халыкны аңа каршы котырту өчен эшләнгән булып чыкты. Имеш, менә кемнәр шәһәрнең тынычлыгын боза, менә кемнәр «Маяк»ка каршы эшләп ята...

Гөлҗиһанны күреп, халык аның өстенә ябырылды. Барысы да аны тарта-йолкый, нәрсәдәдер гаепли, нидер таләп итә иде. Телевидение бу хәлне рәхәтләнеп төшерә, журналистлар халыкның һәр сүзен ашыга-ашыга язып баралар. Милиция бу эшләргә катнашмый, ул Гөлҗиһанны яклап бер сүз дә әйтми, барысы да урам ихтыярына куелган иде. Югыйсә аларның күбесен Гөлҗиһан яхшы белә, болар заманында аның кулында дәваланган шәһәр халкы иде. Рактан һәм нурланыштан үләргә торган мескеннәр иде...

Гөлҗиһан, котырган халык кулыннан чакка-көчкә котылып, суд бинасына килеп керде. Әмма монда да шул ук хәл иде, бөтен коридорлар, суд залы халык белән шыгрым тулы, әйтерсең бөтен шәһәр кубарылып чыккан. Һәм күпләрнең кулларында Гөлҗиһанга каршы язулар. Алар аны «Маяк»-ка, шәһәргә каршы эшләүдә гаеплиләр, хәтта үзен хөкем итүне таләп итәләр.

Судья да бөтенләй чит-ят кеше булып чыкты, аны махсус Чиләбедән китергәннәр, диделәр. Бер якта «Маяк» вәкилләре һәм аларны яклаучылар гаскәр кебек тезелеп утырган, икенче якта Гөлҗиһан берүзе. Аның адвокаты да, яклаучысы да юк. Бу юлы аның янында кыя кебек ире дә, утка керергә әзер торган авылдашлары да юк. Алар инде барысы да салкын кабердә яталар. Алар хакына, бу дөньядан зур газаплар белән киткән авылдашлары хакына, Гөлҗиһан бүген хаклыкны әйтергә тиеш. Ә хакыйкать, дөреслек аның ягында. Бүген бер Иртәш кенә түгел, бөтен дөнья аңа каршы чыкса да, Гөлҗиһан биредә дөреслекне әйтеп китәргә тиеш. Кисәтеп китәргә тиеш...

— Мин — медик, гомерем буе Иртәш шәһәр больницасында шәфкать туташы булып эшләдем, — дип башлап китте Гөлҗиһан сүзен, эчтән бисмилласын әйтеп. — Мин сезнең күбегезне беләм, сез мине беләсез. Бу залда минем белән бергә эшләүчеләр дә утыра әле. Алар белә: миндә өченче дәрәҗә яман шеш, бавырым инде тугыз тапкыр зурайган, йөрәгемнең бер клапаны эшләми, бизләрем нурланыш алган, эшчәнлекләре бозылган... Илле яшемдә мин икенче группа инвалидлыкка чыктым. Ә минем әби-бабаларым туксанга җи-

теп үлде, йөз дә биш яшькә җиткән бабам әле дә исән. Безнең нәсел озак яшәүчеләр белән дан тоткан. Бала чакта мин дә бик тере, чая бала идем, авыруның нәрсә икәнлеген дә белмәдем. Бу газаплар барысы да илле җиденче елда «Маяк» шартлаганнан соң башланды. Мин ай буе кан косып яттым, борын-колакларымнан шаулап кан акты, күзләрем күрмәскә әйләнде, башымдагы чәчләрем коелып бетте. Мин ул вакытта ук көчле нурланыш, радиация алган булганмын, әмма ул чагында аны миңа беркем әйтмәде. Киресенчә, мәктәптәге бөтен балаларны радиацияле урыннарга эшкә кудылар, милиция сагы астында. Без класста утызга якын бала идек, хәзер ике кеше калдык, барысы да рактан үлеп бетте. Бу хәлләрдән соң бер Татар Караболагы авылында гына да ике меңнән артык кеше үлде, барысы да диярлек рактан һәм нурланыштан. Безнең авыл 1959 елда ук икенче урынга күчерелергә тиеш булган, әмма күчерелмәгән. Караболак халкы бүген дә радиациядән зарар күрмәгән булып исәпләнә, судларда аларның гаризаларын карап, кире боралар, хөкүмәттән бернинди ярдәм юк. Караболак халкының бөтен фаҗигасе — «Маяк»тан, анда булган атом шартлавыннан, аннан бүген дә даими таралып яткан радиациядән. Без шуны яхшы аңладык: «Маяк» шушы хәлдә эшләп торганда, анда бер кеше дә исән калмаячак!

Шушы урында судья аны туктатуны кирәк тапты.

— Менә сез уйлап карагыз әле, — диде ул, бик белдекле кыяфәт белән. — Шушы бер кечкенә авыл өчен бөтен илгә хезмәт күрсәтүче объектны туктатуны сез дөрес дип табасызмы? Ул авылның радиациядән зарар күрүе бер документ белән дә расланмаган, теркәлмәгән, исбатланмаган. Хәзер бөтен җирдә авыллар бетә, чөнки халык шәһәргә күчә, шәһәрдә яши. Аннан фаҗига ясарга кирәкме икән? Әмма моңа карап, беркемнең дә башына үзләрен эш белән тәэмин итә торган завод-фабрикаларны яптыру, шәһәрләрне бетерү идеясе килми. Дәвам итегез, тик судка кирәген генә сөйләгез. Монда бүген сезнең авыл мәсьәләсе каралмый, «Маяк», шәһәр язмышы карала...

Журналистлар судьяның һәр сүзен чатыр-чотыр камераларга яздырып бардылар, туктаусыз фотога төшерделәр. Залдагы урысларга да әллә кайдагы татар авылы кирәкми, алар «Маяк» турында, Иртәш турында сүз башлауны көтәләр иде...

— Иртәш хакында да шул ук сүз, — диде Гөлҗиһан, үзен кулга алырга тырышып. — Бу шәһәр атом казаны өстендә утыра, теләсә кайсы вакытта ул күккә очарга мөмкин. Чернобыль кебек. Хәер, биредә илле җиденче елгы шартлау Чернобыльгә һәм Хиросимага караганда йөзләрчә тапкыр көчлерәк булган, әмма бу хакта халыктан яшергәннәр, күпме

кеше үлгәне дә билгесез. Үзегез беләсез, Россиядә генә түгел, бөтен дөньяда мондый куркыныч атом объекты юк. Иртәш тирәсендәге күлләрдә, җир астында һәм җир өстендә хәзер бер миллиард кюри атом калдыклары саклана, алар миллионлаган тонна белән исәпләнә. Дөньяның унсигез иленнән бирегә атом калдыклары кертелә. Дөньяның бер иле дә бу үлем куркынычын үзендә сакларга теләми, ә Иртәшкә китереп ташларга ярый булып чыга. Шуның өстенә көне-төне берничә атом реакторы эшләп тора, көне-төне тирә-якка радиация тарала. Әгәр шушы атом саклагычларында яки реакторларда берәр көчле авария булса, шәһәр урынында калмаячак. Шәһәр генә түгел, Урал таулары да күккә очачак. 2000 елның 9 сентябрендә мондый фаҗига була язып калды бит инде. Галимнәр әйтүенчә, «Маяк»ка сәгать ярым электр энергиясе бирелмичә торыла, нәтиҗәдә реакторларны суытырга су кудыра алмыйлар. Әгәр «Маяк»ка электр бирмәү тагы беразга тоткарланса, бу урында йөз Чернобыль була иде, шәһәр урынында җәһәннәм чокыры гына кала иде. Аллаһ безне шул рәвешле кисәтте, саклап калды, ә без һаман гыйбрәт ала белмибез...

Судья тагы сүзгә катнашуны кирәк тапты:

— Менә, күрәсезме, хәтта шундый гадәттән тыш шартларда да «Маяк» исән калган, берни булмаган. Чөнки анда саклану чаралары бик көчле каралган, югары дәрәҗәдәге белгечләр эшли. Бүгенге көндә атом объектларында көчле аварияләр булу мөмкинлеге юк дәрәҗәсендә, чөнки кешелек инде XXI гасырда яши. Бөтен дөнья атом энергетикасыннан, атом көченнән файдалана. Ә карчыкларның фаразлауларына хәзер беркем ышанмый, шомланугa бирешми. Сезнең сүзегез беттеме? Хәзер сорауларга күчәбез.

— Юк, минем сүзем бетмәде әле, — диде Гөлҗиһан кырыс итеп. — Ә мин әйткәннәр алар карчыклар куркытуы түгел, галимнәр кисәтүе. «Маяк», хәтта шартламаган очракта да, тирә-як өчен гаять куркыныч объект, чөнки ул даими радиация чыганагы булып тора. Чиләбе өлкәсендә ярты миллион кешенең нурланышка дучар булуын сез инде беләсез, бу хакта күп яздылар. Бу бит — ярты миллион рак авыруы, ярты миллион бәхетсез, ярты миллион вакытсыз үлем дигән сүз. Ул ярты миллионга без барыбыз да керәбез. Ә инде Иртәшкә килгәндә, безнең шәһәрдә рак белән авыру өлкәгә караганда биш тапкыр күбрәк, бигрәк тә үпкә, ашказаны рагы, кан рагы, калкансыман бизләр рагы күп күзәтелә. Соңгы вакытта Иртәш халкында бавыр һәм ашказаны асты бизе рагы арту күренә, болар барысы да организмга радионуклидлар, бигрәк тә плутоний һәм стронций керүдән барлыкка килә. Болар исә организмнан бер кеше гомерендә генә чы-

гып бетмиләр, кырык буынга хәтле баралар, бөтен нәселне җимерәләр, черетәләр. Мондый авырулардан бары тик авырулар гына туа, шуны беркайчан да онытмагыз. Мин сезгә боларны, медик буларак, белеп сөйлим. Беркемгә дә сер түгел, шәһәрдәге җитмеш процент халык психик яктан тайпылышлы, күп гаиләләрдә дебиль, тиле балалар бар. Инде мин тумыштан телсез-чукрак, сукырлар турында әйтеп тә тормыйм, үз балаларым да шундый булды. Шәһәрдә һәр биш кешенең берсе наркоман, сез моны үзегез дә яхшы беләсез. Менә кемнәр кулына калырга мөмкин киләчәктә атом реакторлары — тиленәр һәм наркоманнар кулына. Шушы көн килеп җиткәнче, хөкүмәт «Маяк»ның эшчәнлеген әкренләп туктату турында уйлый башларга тиеш. Бүген Иртәштә үлем туууга караганда күбрәк, зиратларда яшьләргә урын юк. Шулай булгач, без кемнәр өчен, нәрсә хакына тотабыз соң бу үлем объектларын, «Маяк»ларны? Чит илләрнең үзләренә кирәкмәс пычракларын саклау өченме? Үз халкыбыз бүген шулай күз алдында кырылып бетеп баргач, нигә кирәк безгә ул атом акчалары? Бүген уч тутырып хезмәт хакы алу өчен, без киләчәгебезне утка салабыз бит! Атом утына! Менә шул хакта уйлагыз, шәһәрдәшләр! «Маяк», һичшиксез, үзенең эшчәнлеген туктатырга тиеш, чөнки ул бүгенге көндә кешеләргә каршы, кешелеккә каршы эшли. Бүген моны мин әйтәм, иртәгә меңнәр, миллионнар шушыны таләп итәчәк. Бу эшне бүгеннән башламасаң, иртәгә соң булырга мөмкин. Шуңа күрә мине яклагыз, чөнки бу үзегезне дә яклау булачак. Минем сүзем бетте.

Бу сүзләрдән залдагы халык тынып калды. Инде беркемнең дә, «Маяк»ны яклап, Гөлҗиһанга каршы кычкырасы килми иде. Чөнки аның сөйләгәннәре барысы да дөрес, барысы да алар турында иде. Журналистлар чатыр-чотыр әле Гөлҗиһанны, әле тынып калган залны төшерделәр. «Маяк» һәм хакимият вәкилләре шунда гына үзләренең нинди зур ялгыш ясауларын аңладылар — алар, үз куллары белән, бу татар хатынына «Маяк»ка каршы үз фикерләрен таратырга ирек биргәннәр иде! Алар Гөлҗиһанны фаш итәргә, тиле, ычкынган хатын итеп күрсәтергә теләделәр, ә үзләре шундый хәлдә калдылар. Чөнки бу татар хатыны халыкны үз сүзләренә ышандыра алды. Ул бары тик дөресен генә әйтте. Бу хакта курыкмыйча, кычкырып, халык алдына чыгып әйтте. Бу мәсьәләдә ул әле берүзе иде, хәзер күпләр аңа кушылырга мөмкин. Шуңа күрә халык аның ягына авып беткәнче, сүзне «Маяк» вәкилләренә, аның яклаучыларына бирергә кирәк иде. Бу залдан бер генә кеше дә «Маяк»ка каршы уй белән чыгарга тиеш түгел. Бу куркыныч вирусны һич кенә дә шәһәргә таратырга ярамый, аны тамырында тотып алыр-

га, корытырга, юк итәргә кирәк. Һәм тиз арада сүзне «Маяк»ның җәмәгать яклаучысына бирергә булдылар. Бу — Гөлҗиһаннар яшендәге чатнап торган марҗа хатыны иде. Гөлҗиһан картасын нәкъ менә ул бастырырга, Гөлҗиһанның сүзләрен ул юкка чыгарырга тиеш иде.

— Мин дә, әле генә чыгыш ясаган дәгъвачы кебек, 1946 елның сентябрендә туганмын, — дип башлап китте ул сүзен, ниндидер эчке бер горурлык белән. — Бу беренче совет атом реакторы «Аннушка»ны төзи башлаган тарихи көннәр булган, шуның хөрмәтенә миңа да Анна дип исем кушканнар. Минем әти-әни бирегә 1945 елның көзендә үк беренче төзү отрядлары белән килгәннәр. Ул вакытта биредә әле шәһәр дә булмаган, «Маяк» та булмаган, тирә-якта урман да сазлык булган. Алар, мал абзарларында яшәп, менә шушы шәһәрне төзегәннәр. Язын-көзен бирегә танктан башка берни белән кереп булмаган. Әти-әнинең сөйләүләре буенча, алар ашарга урамда учакта пешергәннәр, мунчага җәяүләп Кыштымга йөргәннәр. Мин инде баракта үстем, Иртәшнең ул вакыттагы агач тротуарларында уйнадым. Аннан шәһәр уртасында ике катлы берничә таш кирпеч йорт төзеделәр, шәһәр шуннан башланып китте. Боларны ни өчен сөйлим? Чөнки шәһәр минем белән бергә үсте, минем күз алдында күтәрелде. Шуңа күрә, «Маяк» дигәндә, мин Иртәшне күздә тотам, Иртәш дигәндә, «Маяк»ны уйлыйм. Шуңа күрә «Маяк»ны туктату — ул инде шәһәрнең яшәвен дә туктату булачак. Шуңа күрә аларга каршы кем генә, нәрсә генә әйтсә дә, минем йөрәгемә, минем язмышыма килеп бәрелә. Авылдан әзергә генә килеп кергән кешеләр моны аңлый да алмый, кадерен дә белми. Хәтерлим, әле мин беренче класста укыганда, шәһәрдә беренче кинотеатр ачылды. Ул «30 лет Октября» дип атала иде. Миңа ун яшь вакытта, Маяковский исемендәге кинотеатр ачылды, илле сигездә «Маяк» культура сарае эшли башлады. Ә беренче стадионнар, пионерлар сарае, беренче мәктәпләр... Аннан ата-аналарыбыз башлаган эшне без дәвам иттек, без бу шәһәрне, «Маяк»ны мәңгелеккә дип төзедек. Без аның һәр урамы, һәр йорты, һәр объекты өчен бөтен көчебезне салдык һәм шушы хәлдә аны балаларыбызга, оныкларыбызга да калдырырга тиешбез.

Хатын залга күз төшереп алды.

Халык аны тыңлый иде.

Дөрес, Гөлҗиһан сөйләгәндәге кебек, сискәнеп һәм хәвефләнеп түгел, халык аны тыныч кына тыңлап утыра иде. Аннаның сүзләре аларны борчымый да, уйландырмый да. Чөнки мондый патриотик эчтәлекле язмалар соңгы вакытта Иртәш газеталарында күп басылды, халык аларга инде ияләнеп беткән иде. Әмма Аннаның моны сизәрлек башы юк иде.

— Сез карагыз — Иртәш бит бүген чәчәк атып торган шәһәр! — дип дәвам итте ул кайнарланып. — Барыбыз да яхшы белә: аны бит «Маяк» тота, шәһәр «Маяк» акчасына яши, шуны онытмыйк! Минем күп шәһәрләрдә булганым бар, әмма безнең Иртәштән дә матуры, чистасы, бае юк. Аның ябык зона булуы да безнең өчен бик әйбәт әле — теләсә кем кереп йөри алмый. Үзегез беләсез, хәзер куркыныч заман, бөтен җирдә террористлар, беркем тынычлап йоклый алмый, анда шартлау, монда заложниклар. Ә Иртәш мөселман террористлары, чечен боевиклары өчен бикле! Бу да «Маяк» аркасында бит. Без монда рәхәтләнеп тыныч йоклый алабыз, кайчан террористлар кереп шартлатып китәрләр дип куркып ятмыйбыз. Ә «Маяк»ны япсаң, капкалар ачылачак, бөтен әтрәк-әләм монда кереп тулачак. Чегәне, сукбае, исереге, наркоманы, террористы, боевигы. Бәлки, кемнәргәдер нәкъ шушылар кирәктер дә. Әмма шәһәр халкына мондый тормыш кирәкми. Шуңа күрә без беркайчан да «Маяк»ны ябарга ирек бирмәячәкбез, шәһәрне куркыныч астына куйдырмаячакбыз!

Җәмәгать яклаучысы Анна Вавилова шулай дәртләнеп сөйләде дә, бик зур эш башкаргандай, урынына барып утырды. Ул бүген үзен шәһәр хәтле шәһәрне саклап калучы милли каһарман итеп хис итә иде. «Маяк» вәкилләре, хакимият кешеләре, судья да тынычланып киттеләр, чөнки шәһәрдә күпчелек халыкның нәкъ менә шулай уйлаганнарын белә иде алар. Журналистлар, Аннаның бер сүзен дә төшереп калдырмыйча, җентекләп язып бардылар.

Шулчак тагы Гөлҗиһан урыныннан күтәрелде:

— Минем җәмәгать яклаучысына соравым бар, — диде ул, бу хатынның гаиләсен исенә төшереп.

— Сораулар мөмкин, сорагыз, — диде судья, теләр-теләмәс кенә.

Чөнки аның дәгъвачыга сорау өчен сүз бирмәскә хакы юк иде.

— Сезнең әтиегез Иван Васильевич Вавилов иде бит?

— Әйе, — диде Анна, кинәт кенә каушап китеп.

Ул хәтта урыннан ук торып басты. Аның бу мәсьәләгә керәсе килми иде...

— Әтиегез нәрсәдән үлде, Анна Ивановна?

— Үпкә рагыннан үлде. Ул яшьли үлде, аңа әле кырык та юк иде...

— Ә әниегез нәрсәдән үлде?

— Ул да яшьли китте. Кан рагы, диделәр...

— Әйе, әниегез больницада минем кулда үлде. Бик газапланып, бөтен каны агып бетеп үлде. Әле аңа илле дә юк иде.

Судья, нәрсәдер сизенеп, Гөлҗиһанны туктатырга ашыкты, аңа «Маяк» турында гына сораулар бирергә кушты.

— Мин сорауларымны «Маяк» турында бирәм дә инде, — диде Гөлҗиһан, аңа игътибар итмичә. — Чөнки җәмәгать яклаучысы Вавилованың әти-әниләре «Маяк» аркасында шушы хәлгә калган кешеләр. Чөнки рак аларда радиация сәбәпле барлыкка килгән. Инде конкрет үзегезгә сорау, Анна Ивановна. Сезнең бер туганыгыз йөрәк белән яшьли үлде, бердәнбер сеңелегез Сөнкүлдә, тиләләр йортында. Үзегезнең гомер буе балагыз булмады, сез дә өченче дәрәҗә сөяк рагы белән больницада хисапта торасыз. Ирегез менә ун елдан артык инде, шикәр чире белән шешенеп, урын өстендә ята, бөтен нәрсәсе астында. Миңа боларны үләр алдыннан әниегез сөйләп калдырды. Сез «Маяк»тан иң зур зыян күргән кеше бу залда, ул сезнең бөтен нәселегезне черетте, газапка салды. Сез менә органнар үзләре уйлап чыгарган «мөселман террорист»ларыннан куркасыз, ә бөтен нәселегезне кырып салган «Маяк»тан курыкмыйсыз. Сез үзегез аның эшчәнлеген туктату артыннан йөрергә тиеш бит. Сезнең болар хакында уйлаганыгыз булмадымы?

Анна Ивановна әкрен генә урыныннан торып басты. Аның йөзе күгәреп, тимгел-тимгел булып чыккан иде. Иреннәреннән кан качкан һәм дер-дер килеп тора. Ул башта тынып калган залга карады, аннан хафага төшкән «Маяк» вәкилләренә күз төшереп алды, иң соңыннан төсләре уңган зәңгәр күзләрен Гөлҗиһанга батырды.

— Чөнки мин үзем турында уйламыйм, ил, халык турында уйлыйм! — диде Анна, горур башын югары чөеп. — Үземә авыр дип, мин беркайчан да атам-анам төзегән шәһәрне җимерү юлына басмаячакмын! Мин бөек урыс милләтенең, бөек Россиянең, шушы шәһәрнең патриоты, сездән аермалы буларак, аның өчен көрәшүче урыс хатыны. Һәм кабатлап әйтәм: без беркайчан да «Маяк»ны юк итәргә юл куймаячакбыз. Чөнки ул ил өчен кирәк, Россия өчен кирәк, халыкны саклау өчен кирәк!

Гөлҗиһан сорауларыннан урындыкка сеңеп беткән зал, Анна сөйли башлагач, уянып китте. Әйтерсең лә аларда яңадан Ткаченколар рухы уянды, әйтерсең лә Иртәшкә тагы Сталин чорлары әйләнеп кайтты.

— Әйе, бирмәячәкбез! — дип дәвам итте Анна, залдагы милләттәшләреннән рух алып. — Һәм сездән, татарлардан аермалы буларак, биредә утыручылар үзләренең балаларын гарәп илләренә качырмадылар. Без, урыс халкы, ни күрсәк тә, ил белән бергә күрергә өйрәнгән. Без илнең кадерен белергә, аның өчен көрәшергә, аны сакларга өйрәнгән. Әгәр ул елларда «Маяк»та атом бомбасы ясамаган булсалар, Россияне күптән юк итеп ташлаган булырлар иде инде. Хәзер дә ул шулай, менә шушы коралларыбыз булган өчен генә бездән

куркалар, безнең белән санлашалар. Гомеремне яңадан башларга туры килсә, мин ике дә уйламыйча, анысын да Иртәшкә, «Маяк»ка багышлар идем. Чөнки ул минем тормышым, ул минем язмышым...

Һәм хатын, суд залын тетрәтеп, барысын да аптыраушта калдырып, кычкырып шигырь укып җибәрде. Аны туктатучы булмады, чөнки бу шигыре белән дә ул «Маяк»ны яклый, Гөлҗиһан сөйләгәннәргә каршы чыга иде.

Нам судьбою выпало жить иль умереть,
Но страну родную от огня сберечь.
Нелегко нам было, может, как в бою,
Но судьбу, товарищ, я благодарю.

Мы пришли в тот город на нелегкий труд,
Здесь заслон Отчизне сверстники куют.
Кажется, недавно кончилась война,
Но защиту снова требует страна.

Плачет Хиросима, смертию объят,
Мы с тобой обязаны защитить их, брат.
Нам судьбою выпало — жить иль умереть,
Но страну родную от огня сберечь.

И ряды редели, словно от огня,
Падает подружка, славная моя.
Покорили атом, многих нет теперь,
Открывай, товарищ, им в бессмертье дверь!

...Нелегко нам было, может, как в бою,
Но судьбу, товарищ, я благодарю...

Халык, кайда утырганын да онытып, дәррәү кул чаба башлады.

Күпләрнең күзләрендә яшь иде, шушы рухи мизгелләр хакына алар атом казанына кереп ятарга да әзер иделәр. Халык бераз тынычлангач, сүзне «Маяк» вәкиленә бирделәр. Ул да Аннаның чыгышыннан бик тәэсирләнгән, ул үзен, чыннан да, ил өчен бөек эшләр башкаручыларның берсе итеп хис итә иде.

— Анна Ивановнаның бу чыгышыннан соң, мин аның алдында тезләнеп рәхмәт әйтергә әзер, — дип башлап китте ул үзенең сүзен. — Һәм «Маяк»ны, шушы шәһәрне төзүчеләргә без зур рәхмәтле, аларның исемнәре мәңге онытылмас. Әйе, инде хәзер сер түгел, «Маяк» атом коралы җитештерү өчен, илебезне саклау өчен төзелде. Аны юкка гына «Ядерный щит страны» дип атамыйлар. Ул хәзер дә шул рольне башкара. Әлбәттә, монда бер авыру хатынның сүзләренә җавап биреп тормаска да мөмкин булыр иде, чөнки инде барысы да ачык — халык безгә «Маяк»ны ябарга беркайчан да

ирек бирмәячәк. Чөнки, үзегез ишеттегез, «Маяк» халыкка кирәк, «Маяк» Иртәшкә кирәк, «Маяк», ниһаять, илгә, Россиягә кирәк! Мин хәтта дәгъвачы ханымның да бу залдан шуны аңлап китүен телим. Ягъни ул судка язган гаризасын үзе үк кире алырга тиеш. Һәм халыкка үзенең ялгышуын аңлатырга. Үзегез уйлап карагыз: күпме көч кергән бит бу шәһәргә һәм «Маяк»ка?! Һәм нинди елларда! Сугыштан соң бөтен ил белән атом промышленностена нигез салып кара әле! Әйе, бу юлда корбаннар да булды, чөнки без, дөньяда беренчеләрдән булып, атомны буйсындырдык, аны ил иминлеге өчен эшләргә мәҗбүр иттек. Һәм эшләттек тә. Хәзер күз алдына китереп карагыз: кемнәрнеңдер таләбе белән «Маяк» үзенең эшчәнлеген туктатты ди. Ягъни ябылды. Болай әйтү көлке, әлбәттә. Гөрләп эшләп яткан, илгә миллиардлаган доллар керем китергән объектны беркем дә ябарга ирек бирмәячәк. Ил башында акыл ияләре утыра бит әле. Әйтик, шулай да ниндидер сәбәпләр аркасында «Маяк» ябылды ди. Моннан кем ота, иптәшләр, кемгә яхшы булачак? Бөтен шәһәр эшсез калачак бит, төзелешләр тукталачак, больница, мәктәпләр ябылачак, тормыш үзе тукталачак! Моны хәтта күз алдына китерергә дә куркыныч. «Маяк» ябылганнан соң Иртәшнең хәле ничек буласын беләсең килсә, Чернобыльдән соң Припять шәһәрен күз алдына китер. Менә анда чын мәгънәсендә үле зона. Кешеләр дә юк, эш тә юк, төзелешләр дә юк, тормыш та юк. Ә бездә тормыш гөрләп бара бит, көн саен туйлар, балалар туып тора, яңа йортлар салына, сәүдә чәчәк ата, кибетләрдә җаның ни тели, шул бар. Иң мөһиме — «Маяк» хезмәт хакын вакытында бирә һәм яхшы бирә, башка урыннарда байлар да моның хәтле ала алмый. Аннан, мәсьәләнең тагы бер ягы бар бит әле — «Маяк» үзенең эшчәнлеген туктатса, монда тупланган миллионлаган тонна атом калдыгы өчен беркем җавап бирмәячәк бит. Шәһәр дә, атом каберлекләре дә ачык калачак. Монда террористлар да, ваххабилар да, мөселманнар да рәхәтләнеп кереп йөри алачаклар. Ә моның ахыры нәрсә белән беткәнен үзегез дә яхшы беләсез. Шуңа күрә «Маяк»ны ябу мәсьәләсен бүтән кузгатмаска, бу мәсьәләне күтәргән кешенең үзенә карата җинаять эше ачарга дигән тәкъдим бар. Чөнки интернетта «Маяк»ка яла яккан язмалар күренү сәбәпле, кайбер илләр бирегә атом калдыкларын китерүне туктаттылар. Бу исә ил миллионлаган доллар акчасын югалтты дигән сүз, шәһәр ярлыланды дигән сүз. Алга таба без үзебезне якларга мәҗбүр булачакбыз. Чөнки «Маяк»ка каршы бару ул — ил иминлегенә каршы бару, Россиягә каршы эшләү. Моны бары тик шулай гына бәяләргә була...

Гөлҗиһанның соңгы сүзе кыска булды.

— Минем сезгә сүзем бетте һәм өстемнән бурычым да төште, — диде ул, зур сабырлык белән. — Инде соңгы сүзне тормыш үзе әйтер. Безнең динебездә «бер халыкта начарлыктан тыючы калмаса, ул кавемгә Аллаһның рәхмәте киселә» дигән кисәтү бар. Бу җир-сулар, бу дөнья һәм кешелек, безгә Аллаһ тарафыннан әманәт итеп бирелгән, без аны кыямәт көненә чаклы сакларга тиеш идек. Әмма бу буыннан, бу илдән, бу «Маяк»тан дөньяга, киләчәккә нәрсә кала? Агуланган җирләр, эчәргә яраксыз су, радиацияле һава һәм череп яткан кеше үзе. Боларның барысы өчен дә Аллаһ җавап таләп итәчәк. Бу суд залында теләсә ничек бер-берегезне алдый аласыз, әмма Аллаһны алдый алмассыз. Һәм соңгы карарны да Ул чыгарачак. Җәзаны Ул бирәчәк. Шул көнгә әзерләнегез...

Алга таба бу залга, бу кешеләргә сөйләүнең мәгънәсе юклыгын аңлады Гөлҗиһан.

Боларга дөреслек түгел, бүген яшәп калу кирәк иде.

Шуышып булса да.

Агу ашап булса да яшәп калырга кирәк иде...

Суд Гөлҗиһанның гаризасын кире какты, дәгъвасын канәгатьләндермәде. Зал моны гөрләтеп кул чабып каршы алды. Иртәш халкы Гөлҗиһанны җиңүе белән бәхетле иде. Беркем аның янына килмәде, ни яхшыдан, ни начардан бер сүз әйтмәде. Кайберәүләр, аның күзенә карарга оялып, әйләнеп үтәргә тырыштылар, чөнки эчтән генә булса да Гөлҗиһанның хаклы икәнлеген белә иде алар. Гөлҗиһан үзе дә судның шулайрак бетәсен чамалаган иде, әмма мондый талату оештырырлар дип, ул күз алдына да китерә алмады. Ә аңа каршы бөтен шәһәрне күтәргәннәр иде...

Кичен Иртәш һәм Чиләбе каналларыннан шушы судны күрсәттеләр. Хәтта Мәскәү телевидениесе дә бу хакта берничә тапкыр телгә алды. Атом комбинатын күкрәге белән яклаган Анна бер мизгел эчендә Россиянең милли героена әйләнде. Атомчыларга каршы суд эше кузгаткан татар хатыны Гөлҗиһан шушы минуттан Россия дошманына әверелгән иде...

Ул арада аңа бертуктамый телефоннан шалтырата башладылар.

Кемнәрдер аны кискен гаепләде, кайберәүләр бу батырлыгы өчен рәхмәт әйттеләр. Рәхмәт әйтүчеләр Караболактан һәм Чиләбедән иде. Бигрәк тә Чиләбе экологлары суд залындагы бу хәлләрне күреп тетрәнгәннәр. «Сез бөтен дөньяга «Маяк» хакында чын дөреслекне җиткерә алдыгыз, — диделәр алар. — Тегеләрнең бар сөйләгәннәре шапырыну, демагогия, күзгә төтен җибәрү, патриотик хисләр белән уй-

нарга тырышу булды. Сез исә фактлар белән дәлилләп сөйләдегез, рәхмәт сезгә, Гөлҗиһан ханым! Чиләбе халкы Сезнең яклы, чөнки иртәшлеләрнең акча өчен агу йотарга да әзер булуларын биредә яхшы беләләр. «Маяк»ның радиациясе безгә дә килеп җитте бит инде, шуңа күрә бу атом монстрына каршы көрәшергә бөтен өлкәне күтәрергә кирәк. Суд карарын кулга алуга, Чиләбегә килегез, өлкә судына жалоба язарбыз. Анда да кире борсалар, бергәләп Мәскәүгә хәтле барып җитәрбез. Аннан соң әле халыкара судлар бар, анда мөрәҗәгать итәрбез. Без үз хокукларыбызны бары тик шулай гына яклый алабыз. Иң мөһиме — ахыргача нык булыгыз, чөнки дөреслек сезнең якта. Ә без Сезгә ярдәм итәргә һәрвакыт әзер...»

Бу сөйләшүдән соң Гөлҗиһанга җиңел булып китте.

Ул үзенең ялгыз түгеллеген аңлады.

«Маяк» бер аны гына түгел, бик күп кешеләрне борчый икән, әмма алар барысы да судка хәтле барып җитә алмый. Әйе, Гөлҗиһан әйтергә теләгән бар сүзен дә күзләренә карап, бөтен шәһәр алдында әйтте. Халыкка «Маяк» турында, үз тормышлары турында дөреслекне җиткерә алды. Кисәтү бурычы инде аның өстеннән төште. Әлбәттә, ул Чиләбегә дә, Мәскәү судларына да барып караячак, Алла теләсә. Халыкара судларга да мөрәҗәгать итәр, исән булса. Һәм шушында кешеләр каршында Гөлҗиһанның бурычы үтәлгән булыр. Үтәлгән булыр...

## Унтугызынчы бүлек

Чиләбе өлкә суды Иртәш шәһәр судының карарын үз көчендә калдырды. Инде соңгы суд Мәскәүдә көтелә иде. Шулай ике арада йөри торгач, кыш та үтте, язлар, җәйләр дә үтеп киттеләр, тагы көзләр җитте. Ул арада Караболактан да китәсе кешеләр китеп, таралаcылар таралып, үләселәр үлеп бетеп бара иде. Бу елда үлем-җитем бигрәк тә күп булды, Гөлҗиһанның иң якын кешеләре берәм-берәм якты дөньядан китеп бардылар. Миасста Фәргатьнең әнисе үлеп китте, аны Караболакка алып кайтып күмделәр. Җеназаны Таһирҗан бабай укыды. Чөнки чечен гаиләсе, Чиләбедән килеп тикшерүләргә түзә алмыйча, авылдан киткән булып чыкты. Алар да Мәккәгә, Абдрәхимнәр янына барып урнашканнар. Сөнкүлдә Җәүһәрия түти үлеп китте, анда татар зираты булмаганлыктан, аны да Караболакка алып кайтып күмделәр, аңа да Таһирҗан бабай җеназа укыды. Иртәштә Таифә җиңгәй Гөлҗиһанның кулында җан бирде. Чиләбедән кызлары Рабиганың мәетен алып кайттылар, аңа да Таһирҗан бабай

җеназа укыды. Гөлҗиһанның үзәк-бәгырьләрен өзеп, бер-бер артлы ике энесе үлеп китте, хатыннары аларны да Караболакка алып кайтып күмделәр. Аларга да Таһирҗан бабай җеназа укыды.

Дөнья шулай тоташ үлемнәрдән торган кебек тоелса да, Гөлҗиһанның тормышында дөньяларга сыймас шатлыгы да бар — кызы Гадилә ир бала тапты. Бу турыда шатлыклы хәбәрне аңа Мәккәдән чечен гаиләсе хәбәр итте. Чөнки Абдрәхимнең гарәпчә сөйләгәнен Гөлҗиһан аңламый, ә кызы белән улы телсез. Шулай итеп, чит кешеләр аша булса да, ул үзенең әби булганлыгын белде. Мусаның әйтүенчә, малай гаять таза, гәүдәле булып туган, йөзе-тәне шикәрдәй ак, күзләре яшькелт, ди. Аны күрүгә, «Алып бала» дигәннәр. Иң мөһиме — бөтен җире сау-сәламәт, күзләре күрә, колаклары ишетә, теле дә ачылырга тиеш икән. Балага Баһадур дип исем кушканнар. Моны ишеткәч, Гөлҗиһан бер елады, бер көлде, шатлыгын кем белән уртаклашырга белмәде. Күңеленнән иренә эндәште: «Оныгыбыз бар бит, Фәргать», — дип, шатлыгын сөйләде. Әти-әнисенә, әби-бабасына куанычын җиткерәсе килде. Тик алар барысы да Караболак зиратында ята иде. Гөлҗиһан, авылга кайтып, шатлыгын Таһирҗан бабасы белән уртаклашты, бушап калган Караболак урамнарына таратты, Аллакүлгә барып сөйләде. Ком чүлләрендә булса да Алып Ханнар нәселе дәвам итә иде, Мәккә шәһәрендә Баһадур исемле татар малае үсеп ята иде.

Ул арада, бөтен өйне яңгыратып, тагы телефон шалтырады.

Гөлҗиһан тавышыннан аңлады, бу — чит илдән иде. Мәккәдән, балаларыннан булырга тиеш, чөнки алар сөйләшергә яннарында кеше булганда, гел шалтыратып торалар. Үзләре сөйләшә алмагач, ярдәмгә кеше кирәк. Әниләренең тавышын ишетмәсәләр дә, исәнлеген белергә кирәк...

Бу юлы да чечен Муса булып чыкты.

Бу юлы да ул шатлыклы хәбәр җиткерә иде.

— Барыбыз да исән-сау, Гөлҗиһан апа, — диде ул. — Абдрәхим дә, Гадел белән Гадилә дә, кечкенә Баһадур да, минекеләр дә исән-саулар, барысы да менә монда басып торалар, сезгә сәлам әйтәләр. Менә безнең яныбызда бер татар кызы да бар, Казаннан, Әминә исемле, Гадел белән бергә укыйлар монда. Без җыелышып уйлаштык та, яшьләрне кавыштырырга кирәк дигән фикергә килдек, Гөлҗиһан апа. Үзләре дә бер-берләрен охшаталар кебек. Икесе дә риза. Инде сезнең рөхсәтне сорыйлар, Гөлҗиһан апа. Гадел үзе шалтыратырга кушты. Сез ризалык бирсәгез, без монда аларга никах укырбыз, иншаллаһ!

Бу хәбәрдән Гөлҗиһанның башлары әйләнеп китте.

Гаделнең никахы? Казан кызы белән? Кем икән соң ул

кыз, әти-әниләре кемнәр, милли, дини ягы ничек? Аның шуларын да беләсе килә иде.

— Менә Әминәнең үзенә бирәм, апа, — диде Муса.

— Апа, исәнмесез? — дип, Әминә татарча сөйләшә башлады.

Бу сүзләрне ишетү белән, Гөлҗиһанның күзләренә яшь килде. Ерак Мәккә шәһәреннән аның белән татар кызы сөйләшә иде, һәм ул Гаделнең тормыш иптәше булачак.

— Исәнме, кызым, — дип эндәште аңа Гөлҗиһан, шунда ук якын итеп.

— Мин беренче тапкыр үземә кызым дип әйткәннәрен ишетәм, — диде теге баштан Әминә, яшь аралаш. — Әтиәнием мин кечкенә вакытта ук үлгәннәр, ятим бала мин, апа. Гадел абый миннән күпкә олы, ул миңа әтиемне дә, абыемны да, башка туганнарымны да алыштыра. Әлбәттә, миңа сездән бу хакта сорарга уңайсыз, әмма миңа Гадел абый әйтергә кушты. Сез ризалык бирсәгез, без никах укытыр идек. Бергәләп тормыш башлап җибәрер идек. Сез миңа әнием булыр идегез.

Бу сүзләрдән инде Гөлҗиһан үксеп елый иде.

Аның гомерендә бер тапкыр да күрмәгән бу кыз баланы кысып-кысып кочаклыйсы, аркасыннан сөеп, яратуын, ризалыгын белдерәсе килде. Әмма ике арада таулар һәм диңгезләр, урманнар һәм далалар җәйрәп ята иде шул.

— Мин риза, мең риза, кызым, — диде ул, күз яшьләрен сөртеп. — Бер-берегезне саклагыз. Улым бик әйбәт минем. Рәхмәт сиңа, кызым, кире какмагансың. Җәйгә, Алла теләсә, Караболакка кайтырсыз, шунда күрешербез дә, иншаллаһ.

— Без башта никахка тиз генә сезне дә чакыртмакчы идек, — дип дәвам итте Әминә. — Визалар эшләтү озак булыр, дидек. Хаҗ вакытында барыбер сезне көтәбез...

— Насыйп булса, килермен, кызым. Ә никахны укытыгыз, тормыш корып яши башлагыз. Насыйп булса, күрешербез дә. Улымны, Гаделемне сакла, кызым. Балаларыгызны татарчага өйрәт, аларга милләт турында сөйлә, безнең Алып Ханнар нәселе турында аңлат. Аларны мөселман итеп тәрбияләгез. Безнең хакта, әби-бабалары турында сөйләгез...

Гөлҗиһан үзенең васыятьләрен әйтеп калырга ашыкты.

Ул тәкъдир сәгатенең әкренәюен, туктарга вакыты җитеп килүен сизенә иде. Менә аның соңгы теләге дә тормышка ашты — улы өйләнә. Улы аннан ялгыз калмаячак. Аның янында хәләле булачак. Татар кызы. Казан кызы Әминә. Милләт хәзер аларның балаларында дәвам итәчәк. Алып Ханнар нәселе өзелмәячәк, кайда гына яшәсәләр дә, татар булып, мөселман булып калачаклар.

Бу хәбәрдән Гөлҗиһан озак йокыга китә алмады.

Кайгылы хәбәрләрне күп ишеткән, күп югалтулар кичергән күңеле шатлык каршында югалып, йомшарып калды. Бу төндә аның күз алдыннан бөтен гомере үтеп киткән кебек булды. Караболагы, Чиләбесе, Иртәше... Шушы уйларга бирелеп, йокылы-уяулы ятканда, аның яныннан, бәхетле елмаеп, ире Фәргать үтеп киткән кебек булды. Улының мөселман-татар кызы белән никахлашасын ишетеп, аның да рухы шатлангандыр, мөгаен. Ул янәшәсендә генә улы Баһадурның җылысын тойган кебек булды. Туганнарының бу кара мәкер иленнән китеп, мөселманнар арасында бәхет табуларына аның да рухы шат булгандыр, куангандыр. Гөлҗиһанның күз алдыннан берәм-берәм карттай-картнәйләре, әти-әнисе үтеп киттеләр. Алар барысы да Гөлҗиһанның шатлыгын уртаклашалар, оныкларына фатиха бирәләр кебек иде.

Гөлҗиһан бик ерак заманда күргән төшен исенә төшерде.

Шушы игезәкләр телсез-чукрак тугач, ул бик нык борчылган иде, хәтта авыруга сабышты. Шул чагында аңа төшендә Аллакүл буенда Хозыр Ильяс кебек бер бабай килде. «Кайгырма, бу балаларың сезгә җәннәткә юлны ачачаклар», — дигән иде ул. Гөлҗиһан Мәккә җирләрендә, Кәгъбәтулла янында тезләнеп намаз укыган балаларын күз алдына китерде. Аның үзеннән соң дога кылучы балалары кала иде. Ана өчен моннан да зур бәхет була аламы? Аның бөтен гомере шушының өчен әзерлек булган икән. Аллаһның авырлыклар белән сынап каравы булган. Сукыр Фәргать белән кавышуы да, телсез-чукрак балалары тууы да сынау булган. Инде хәзер соңгы сынау калды...

Гаделнең никах хәбәреннән соң Гөлҗиһанның тормышында инде нидер төгәлләнгән, тәмамланган кебек булды. Инде барысы да урнашып, үз урынын алып бетерде. Инде гомер йомгагы да сүтелеп бетте. Гомер дә бетеп килә. Гөлҗиһан моны тәне белән дә, җаны белән дә тоя, сизә. Тәнендәге һәр күзәнәк аңа көне-төне шул хакта искә төшереп тора. Аларны инде көчле дарулар да алмый, баса алмый. Җанын көнетөне тәкъдир сәгате кисәтә: «Син әзерме? Син әзерме? Вакытың җитә... Гомерең бетә... Күчәсең... Күчәсең... Күчәсең...»

Шуңа карамастан, Гөлҗиһан һәр иртәне аягына торып баса.

Һәр көн дөньяга «Маяк» турында, аннан янаган куркыныч турында хәбәр тарата. Һәр көн яза, яза, яза... Һәм соңгы судка әзерләнә. Гөлҗиһан калган бөтен көчен шуңа бирә, аждаһаның оясына барып, ул хакыйкатьне сөйләргә тели. Татар хатыны Гөлҗиһан, Караболак халкын яклап, Мәскәүгә судка барырга әзерләнә. Милләтен яклау юлында фәрештәләр юлдаш булсын аңа...

## Егерменче бүлек

Гөлҗиһанның Мәскәүне беркайчан да күргәне юк иде. Дөрес, ул анда күп язды, үзе дә Мәскәүдән күп рәсми җаваплар алды. Әмма аларның барысы да өстән кәгазь төшерү өчен генә җибәрелгән иде. Мәскәү Урал таулары артында булып яткан фаҗигане күрмәде дә күрергә дә теләмәде. Югыйсә андагы бөтен бәхетсезлекне алар оештырган иде бит. Иртәштә атом бомбасы ясау турында Мәскәү карар чыгара, бу төзелеш белән Сталин үзе җитәкчелек итә, НКВД җитәкчесе Берия Иртәштән кайтып керми... Ә «атом атасы» Курчатов, гомумән, ул чорда Иртәштә яши, үләргә генә Мәскәүгә кайта. Менә хәзер Гөлҗиһан үзе Мәскәүгә килә. Иртәштәге атом радиациясе сәбәпле кырылып беткән татар халкының бер вәкиле булып, мәкер үзәгенә килә ул. Бәлки, бердәнбер вәкиле, соңгы вәкиледер. Ул белә — аның Мәскәүне беренче һәм соңгы күрүе. Аңа хәзер, сүзен әйтеп, Караболакка кайтып өлгерергә кирәк. Чөнки тәкъдир сәгате суга башлады...

Гөлҗиһан белән бергә Чиләбедән экологлар һәм хокукчылар да килгән иде. Алар — тәҗрибәле халык, судка журналистларны, радио-телевидение хезмәткәрләрен чакырып өлгергәннәр. Мәскәү өчен «Маяк» проблемасы бик ерак кебек күренсә дә, укымышлы халык моның нәрсә икәнен яхшы аңлый, радиация өчен чикләр юклыгын белә иде. Шуңа күрә Россиядә моңа хәтле булмаган суд процессын яктыртырга күп кеше җыелды...

«Маяк»ны якларга исә Мәскәүнең үзеннән Минатом вәкилләре алынды. Алар бу судка зур әзерлек белән, илдә атом промышленностеның тоткан урыны турында күп мәгълүмат алып килгәннәр иде. Алар тагы «Маяк» мәсьәләсе күтәрелүгә бераз гаҗәпкә калдылар. Чөнки үзгәртеп кору елларында, Чернобыль вакыйгаларыннан соң халык атом темасын бер куертып алды да туктады. Бу елларда күпләрдә бер телем ипи кайгысы булды, кешеләр меңәрләп, миллионлап эшсез урамда калдылар. Мондый шартларда алар атом казанына төшеп эшләргә дә ризалар иде. Инде атом, радиация темасы да бөтенләйгә ябылды дип торганда, менә сиңа мә, ниндидер татар хатыны, «Маяк» өстеннән судлашып, Мәскәүгә хәтле килеп җиткән! Әле халыкара судларга бирү белән дә яный. Һәм таләбе аз да түгел, күп тә түгел — «Маяк»ны яптыру, анда чит илләрдән атом калдыкларын китерүне туктату. Бу инде илнең иминлеге белән бәйле иде, зур акчалар белән бәйле. Шуңа күрә Атом министрлыгы вәкилләре судка үзләре килергә булдылар.

Алларында ак яулык япкан олы яшьләрдәге бер татар хатынын күргәч, алар аптырап калдылар. Алар авызыннан ут чәчеп торган бер «дөреслек эзләүче» белән очрашырбыз дип уйлаганнар иде, ә монда йөзен сагыш баскан бер авыру хатын утыра. Һәм алар, министрлык вәкилләре, шушы мескен татар хатыны белән көрәшергә, бәхәскә керергә тиешләр. Бөтен ил алдында, телевидение, журналистлар каршында.

Ләкин Гөлҗиһан авызын ачып, берничә җөмлә әйтү белән, алар аның кем икәнен аңладылар. Юк, бу мескен, беткән авыл хатыны түгел иде, бу — үз темасын бик яхшы белгән, кулында йөзләгән дәлиле булган, үзенә нәрсә кирәкен бик яхшы аңлаган һәм шуны тормышка ашыру өчен ахыргача барырга әзер көрәшче хатын иде.

— Мин Урал аръягындагы Татар Караболагы авылыннан булам, — дип башлап китте Гөлҗиһан үзенең сүзен. — Моннан алтмыш ел элек ул тирәләрдә «Маяк» комбинаты төзелә башлый, анда беренче совет атом бомбасы ясала. Шул заманнан бирле без атом радиациясе астында яшәргә мәҗбүр. 1957 елда «Маяк»та атом шартлавы булганнан соң, безнең хәлләребез бигрәк тә авырая, халык чебен урынына кырыла башлый. Бүгенге көндә дүрт мең кешелек зур татар авылыннан йөзләп кеше калды, аларының да барысында рак, нурланыш чире. Авыл халкы рактан үлеп бетте, мин боларны, медик буларак, анализ нәтиҗәләреннән чыгып әйтәм. Алар барысы да Чиләбе больницаларында саклана. Әмма аларның авыру тарихларына гомуми диагноз куелган. Шулай итеп, радиациядән агуланып үлгән бу кешеләр, хөкүмәттән бернинди ярдәм дә күрмичә, бу дөньядан китеп бардылар.

Гөлҗиһан шулай диде дә Караболак халкының меңәрләгән авыру тарихын, анализларын, үлем турында белешмәләрнең күчермәләрен суд һәм атомчылар алдына китереп салды. Телевидение аларны тиз-тиз төшерә башлады. Гөлҗиһан тагы сүзен дәвам итте:

— Болар хакында белгәч, үзебезнең даими рәвештә радиациядән агуланып ятканыбызны аңлагач, без авылны башка урынга күчерү мәсьәләсен дә күтәреп карадык. Исән калганнар өчен хөкүмәттән ярдәм сорадык. Әмма безгә кире җавап бирделәр, имеш, Татар Караболагы авылы беркайчан да радиациядән зарар күрмәгән, шуңа күрә халыкка ярдәм дә тиеш түгел. Менә бу хакта суд карарлары, Мәскәүдән, Чиләбедән килгән дистәләгән кире җавап... — Гөлҗиһан аларын да суд һәм атомчылар алдына китереп салды. — Хәзер без авылны күчерү мәсьәләсен күтәрмибез инде, чөнки анда күчерергә кеше калмады, — дип дәвам итте Гөлҗиһан үзе-

нең сүзен. — Ә бит 1959 елда Чиләбе облисполкомы Татар Караболагы авылын башка урынга күчерү турында карар кабул иткән булган, әмма ул үтәлмичә калган. Ә Мәскәүгә «авыл күчерелде» дигән ялган хәбәр киткән. Әмма атомчылар, «Маяк» җитәкчеләре Татар Караболагының күчерелмәгәнен белгәннәр, хәтта бу тирәдәге авылларны күчермәскә әмер биргәннәр. Менә сезгә ул карарлар, ул әмерләрнең күчермәләре...

Гөлҗиһан суд һәм атомчыларның өстәленә кырык биш ел элек язылган документларны китереп салды.

— Шулай итеп, «Маяк»ның борын төбендә яшәүче дүртбиш мең кешелек зур-зур татар авылларын — Мөслимне, Усть-Багарякны, Татар Караболагын — башка урынга күчермиләр, белә торып радиация астында үләргә калдыралар. Менә мин, шушы халыкның исән калган бер вәкиле, хөкүмәт алдына, атомчылар каршына шул сорауны куям: ни өчен татарларны, белә торып, үле зонада яшәргә калдыралар? Ни өчен хөкүмәт ярты гасыр буе аларның газапларын читтән генә карап тора, ярдәмгә килми? Ни өчен татарлар өстендә терелләй атом тәҗрибәсе уздыралар? Татарлар өстендә, дим, чөнки «Маяк» тирәсендә урыс авыллары барысы да башка урынга күчерелә. Ни өчен татар халкы яшәгән җирләрдә гел атом полигоннары, атом станцияләре, атом-төш коралын саклау урыннары, химик һәм бактериологик корал базалары? Ни өчен беренче совет бомбасы татарларның җәннәттәй җирләрендә ясалды? Ни өчен беренче совет бомбасы төркитатарларның Тургай далаларында сыналды? Ни өчен беренче водород бомбасы 1954 елда Ырынбур далаларында, татар авыллары өстендә сыналды? Бу урыннарда хәзер үлән дә үсми бит, ә анда кешеләр калды. Хәзер алар да кырылып бетте инде. Менә сезгә татарлар яшәгән җирләргә урнашкан үлем объектларының исемлеге, карагыз һәм нәтиҗә ясагыз...

Шулай диде дә Гөлҗиһан, кулындагы белешмәләрен атомчылар һәм суд алдына китереп салды. Журналистлар аларны шунда ук төшерә башладылар.

— Шушы хәлләрдән соң, шушы хәтле дәлилләрдән соң, «Маяк»ның атом радиациясеннән бөтен нәселем кырылып беткәннән соң, үзем дүртенче дәрәҗә рак белән кабер читенә килеп басканнан соң, минем бу илне гаепләргә хакым бар, — дип дәвам итте Гөлҗиһан, атомчыларның күзенә туп-туры карап. — Бу ил минем нәселем, минем халкым өстендә атом геноциды уздырды, ул аны терелләй атом казанына салып кайнатты. Әмма бу җинаять татар халкын юк итү белән генә туктамаячак, атом аждаһасы яңадан-яңа корбаннар таләп итә-

чәк. Бер Чиләбе өлкәсендә генә дә бүген ярты миллион атом нурланышы алган кеше яши, хәзер бу корбаннарның күпчелеге урыслар инде, чөнки татарлар үлеп бетте. «Маяк» эшләп торган очракта, биредә нурланыш алмаган, рак белән чирләмәгән бер генә кеше дә калмаячак. Барысы да татарлар язмышын, Татар Караболагы фаҗигасен кабатлаячак. Алга таба «Маяк»тан таралган радиацияне, су, һава, ризык аша кергән радионуклидларны Урал таулары да туктатып кала алмаячак. Чернобыль авариясе тәэсире теге елларда ничек итеп Уралга хәтле килеп җиткән, берәр көчле шартлау булса, «Маяк» радиациясе дә Мәскәүгә хәтле килеп җитәчәк. Ә «Маяк»та соңгы илле ел эчендә генә дә иллегә якын көчле шартлау булды, дөньяга йөзләгән Чернобыль, йөзләгән Хиросима кадәрле атом радиациясе таралды. Чит ил галимнәренең әйтүенчә, шушы илле елда Россиядә илле миллион кешенең рактан үлүе көтелә. Дошманнарга каршы, илне саклауга дип төзелгән «Маяк», атом-төш коралы Россиянең үз халкын юк итә. Әгәр «Маяк» алга таба да эшчәнлеген шулай дәвам итсә, илнең үзеннән дә берни калмаска мөмкин, чөнки биредә бөтен Җир шарын бер минутта юк итәрлек күләмдә — бер миллиард кюри атом калдыклары саклана. Шуңа күрә мин «Маяк»ның эшчәнлеген чикләүне, анда чит илләрдән атом калдыклары кертүне туктатуны таләп итәм. Ахыр чиктә «Маяк» бөтенләй ябылырга һәм бик нык сакланырга тиеш. Чөнки кешелекнең башына җитәчәк үлем аждаһасы шунда яшерелгән...

Министрлык вәкиле аның белән бәхәскә кереп тормады, ул бу авыл хатыны дәрәҗәсендә сүз алып бара алмый иде. Алай да берничә сүз әйтмичә дә булмый, чөнки журналистлар алдында бу татар хатынының сүзен өстә калдырырга ярамый. Шуңа күрә ул басып суд каршында үз сүзен әйтергә мәҗбүр булды:

— Менә бу күренеш фәндә радиофобия дип атала, ягъни радиациядән, атом, радиология белән бәйле нәрсәләрдән курку, аларны күралмау, — дип башлап китте ул вәкарь генә. — Ә һәртөрле фобия ул — авыру галәмәте. Кемдер уттан курка, әмма аңа карап утсыз яшәп булмый. Кемдер суга якын килергә курка, әмма сусыз да яши алмый. Атом белән дә шулай: күп кешеләр аннан курка, аны аңламый, әмма ансыз яши дә алмый. Дөнья энергиясенең күпчелеген хәзер атом энергетикасы тәшкил итә. Медицина баштанаяк лазер, радиобиология, рентген-сканерлар белән коралланган, шулардан башка хәзер кешегә диагноз да куеп булмый. Мин инде армия турында әйтеп тә тормыйм, атом көче булмаса, күп ил-

ләрнең гаскәре яңадан балта белән кылычка кайтып калыр иде. Шуңа күрә бөтен дөньяга билгеле нәрсәләр турында авыз тутырып сөйләп тору миңа уңайсыз. Бәлки, бу яңалыклар авылларга барып җитмәгәндер, әмма мин атом промышленностеның дөньяга ни дәрәҗәдә кирәклеге турында биредә лекция укып тормас идем. Әмма шуны ассызыклап әйтмичә булмый: Көньяк Уралдагы «Маяк» берләшмәсе бүгенге көндә атом промышленностеның төп таянычы, нигезе, горурлыгы ул. Бер Россия өчен генә түгел, бөтен дөнья өчен бу шулай. Биредә дөньяның киләчәк моделе төзелә, кешелекне саклап калу өчен тиңе булмаган зур эш алып барыла. Әлбәттә, андый вакытта бәла-казалар да булырга мөмкин, үзегез беләсез, гади пожардан да күпме кеше үләргә мөмкин, әмма аңа карап, беркем утны куллланудан баш тартмый. Электричество белән дә шулай, ток суга дип, беркем утын сүндереп куймый. Димәк, безгә алга таба саграк булырга кирәк. Ә инде «Маяк»ның эшчәнлеген туктату яки чикләү дигән мәсьәләгә килгәндә, бу — абсурд, җинаятьчел тәкъдим. Үз акылында булган кеше моны беркайчан да әйтмәс. Миңа бу ханымны кызганырга гына кала шушыларны аңламаганы өчен. Бүгенге көндә сез яши торган Иртәш иң матур, иң чиста, иң бай шәһәрләрдән санала. Россиянең башка шәһәрләренә мондый бәхет, мондый тәртип эләкми әле. Ышанмасалар, мин журналистларны анда сәяхәткә чакырам, министрлык моны оештыруны үз өстенә ала...

Шулчак Гөлҗиһанның башына бер фикер килде. Ул үзе белән Иртәштән юлга ашарга дип алган ризыкларын, бакчасында үскән яшелчә-җимешләрне атомчылар каршына чыгарып тезде. Аннан һәрвакыт үзе белән йөртә торган дозиметрын алды да аны ризыкларга якын китерде. Күрсәткеч уклары шунда ук чатырдап югары сикерделәр.

— Менә бу — без көн дә ашый торган ризык, — диде ул, журналистларга карап. — Күрәсез, биредә нурланыш фоны нормадан 50—60 тапкыр артык. Бу исә Иртәш бакчасында, Караболакта үскән ризыкның составында күп күләмдә радионуклидлар — плутоний һәм стронций барлыгын күрсәтә. Ракны, нигездә, нәкъ шулар китереп чыгара. Теләсәгез, мин сезне алар белән сыйлый алам. Курыкмагыз, Иртәшкә килгәч, сезне барыбер шулар белән сыйлаячаклар, чөнки анда башкасы юк...

Моңа каршы беркем бернәрсә әйтмәде, судья Гөлҗиһанга бу ризыкларны өстәлдән җыеп алырга боерды. Суд дәвам итте, әмма аның нәтиҗәсе инде күпләргә билгеле иде. Бөтен дөреслек Гөлҗиһан ягында булса да, ул берьялгызы

атом аждаһасын җиңәрлек хәлдә түгел иде. Шулчак Гөлҗиһанның адвокаты сүз алды, ул Чиләбедән, үзе дә рак белән авыручы хокукчы урыс хатыны иде.

— Без, Чиләбе өлкәсендә яшәүчеләр, барыбыз да дип әйтерлек атом нурланышы, әҗәл тамгасы йөртәбез, — дип башлап китте ул үзенең сүзен. — Радиация милләтләрне аермый, ул бөтенесен дә тигез кыра. Бу атом тамгасы йөртүчеләр хәзер үзләре нурланыш чыганагы булып торалар, ягъни кеше үзе хәзер радиация чыганагы. Шул исәптән без дә. Биредән атом нурланышлы ризыкларны чыгартып ташлатсагыз да, безне кая куясыз? Без, анда яшәүчеләр, Уралдан килүчеләр шундый ук радиация таратабыз. Шулай итеп, хәзер бөтен Россия бер-берсен агулый, бер-берсен нурланыш чиренә дучар итә. Чөнки бүген бөтен Россия атом чүплегенә әйләнде, без шунда җан асрарга, исән калырга тырышабыз. Бу мөмкин хәл түгел. Ә «Маяк» исә бөтен дөньяга куркыныч тудыра. Бер урынга ул хәтле күп җыелган атом калдыгы, радиация чыганагы бөтен Җир шарын шартлатырга яки агуларга җитә. Бу нәрсәне «Маяк» вәкилләре дә, хөкүмәт тә яхшы аңлый, әмма һаман нәрсәгәдер өмет итәләр. Бәлки, бернәрсә дә булмас әле дип уйлыйлар. Ә булгач, соң булачак. Шуңа күрә «Маяк»ны әкренләп ябуга таба бару, аның эшчәнлеген чикләү, анда чит илләрдән атом калдыкларын кертмәү — Россия хөкүмәте алдында торган беренче бурыч булырга тиеш иде. Чөнки сүз илнең иминлеге, кешеләрнең иминлеге турында бара. Әгәр хөкүмәт «Маяк» турында, башка ташландык атом объектлары турында уйламый икән, Россияне атом сахрасына әйләнү көтә. Моның мисалын инде Чиләбе өлкәсендә күрергә була. Моннан илле ел элек кенә җәннәт җирләре кебек урыннар бүген көйгән җиргә әйләнеп калды. Бөтен җир шарында экологик яктан иң пычрак урын булып «Маяк» янында урнашкан Карабаш шәһәре исәпләнә, анда кышларын кара кар ява. Бөтен дөньяда иң пычрак күл булып «Маяк» үзенең атом калдыкларын ташлап бара торган Карачай күле исәпләнә, анда су урынына атом дәрьясы ага. Җир асты юллары буйлап бу атом диңгезе инде Чиләбегә якынлашып килә. Бөтен Урал таулары Россиянең иң пычрак, иң куркыныч, иң хәвефле хәрби объектлары белән тулган, аларның да күпчелеге Чиләбе өлкәсенә туры килә. Шуңа күрә космостан төшерелгән рәсемнәрдә Чиләбе урман-далалары өстендә тоташ кара тап. Бу тап әкренләп Урал тауларының ике ягына — Азия һәм Европа тарафларына тарала. Шушыларны белә торып, ничек бирәдә радиофобия турында демагогия корып утырырга була?! Менә сез Чиләбе өл-

кәсеннән анализ өчен алып килгән бу туфракка гына карагыз: анда кешене бер минутта агулап үтерә торган бөтен авыр металлар бар бит! Ә радиация нормадан мең тапкыр артык!

Шул чагында әллә адвокат хатын туфрак салган капчыгын ялгыш тотты, әллә махсус шулай килеп чыкты, агулы җир шаулап аяк астына сибелде. Ул түрдә — нәкъ «Маяк» вәкилләре һәм судья утырган тирәдә чәчелеп китте. Бер мәлгә бөтенесе дә тынсыз калды. Судья хатын, сикереп торып, чәрелдәп кычкырып җибәрде:

— Хәзер үк җыеп алыгыз бу шакшыны! — диде ул, күтәреп-бүртенеп. — Сезнең ни хакыгыз бар суд залына радиацияле җир алып килергә?! Бу... Бу — диверсия!!! Бу... Бу — террор!!! Җыегыз, диләр сезгә, алып ташлагыз! Милиция! Охрана!

Судьяның шулай чәрелдәп кычкыруына сакчылар йөгерешеп керде.

Алар, берни аңламый, идәндәге туфракка текәлделәр.

Минатом вәкилләре исә, селкенмичә дә, урыннарында утырып калдылар. Алар ярты Россиянең шундый җирләрдә яшәгәннәрен яхшы беләләр иде.

— Без шул туфракта яшибез дә бит әле, — диде адвокат хатын, чәчелгән җирне аягы белән бер тирәгә җыйгалап. — Көн саен шул һаваны сулыйбыз, шул туфракта үскән ризыкларны ашыйбыз, шуннан чыккан суын эчәбез. Ә сезнең бер мизгелдә котыгыз чыкты, гомер һәркем өчен кызганыч шул. Әмма тиздән сездә дә шушы ук хәл булачак, шуны онытмагыз.

Ул арада җыештыручылар кереп, авыз-борыннарын каплап, радиацияле туфракны җыеп алдылар. Суд дәвам итте. Судья Чиләбе өлкәсенең суд карарын үз көчендә калдырды. Гөлҗиһанның үзенә каршы җинаять эше кузгату буенча Иртәш хокук саклау органнарына күрсәтмә китте. Терроризмга каршы көрәш барган бер чорда Иртәштә, атом үзәгендә бер татар-мөселман хатынының «Маяк»ка каршы чыгышлары, алар уйлавынча, Россиянең дәүләт иминлегенә каршы эш дип бәяләнергә хаклы иде. Ә Мәскәүгә, суд залына радиация чыганагы күтәреп килү үзе аерым бер статья иде. Гөлҗиһанның Иртәшкә кайтуына менә шундый эш көтеп тора иде.

Суд карарын кулына алганнан соң, Гөлҗиһан аны Страсбургка, кеше хокуклары буенча халыкара судка җибәрде. Ул шулай ук бу мәсьәлә буенча Гаагадагы халыкара трибуналга да документларын әзерләп озатты. Чөнки ул Россия тарафыннан алып барган бу сәясәтне татарларга каршы атом геноциды дип бәяләде. Дөнья җәмәгатьчелеге дә моңа шулай бәя бирергә тиеш иде.

Мәскәүдә бераз торып, тиешле документларын тиешле урыннарга җибәргәч кенә, Гөлҗиһан туган якларына кайтып китәргә булды. Ул туп-туры Караболакка кайтырга ниятләде. Әллә нишләп бу көннәрдә Таһирҗан бабасын төшендә гел борчулы күрде Гөлҗиһан. Авыл башына чыгып басып, гел Гөлҗиһанны көтә икән. Аннан берьялгызы Аллакүл буйларында йөри, зиратка керә. Һәм шуннан чыкмый. Бу төш Гөлҗиһанның бөтен тынычлыгын алды. Чөнки Таһирҗан бабай инде йөзнең теге ягында, ул теләсә кайсы вакытта китеп барырга мөмкин. Гөлҗиһанның үз хәле дә нәкъ шулай, көчле дарулар белән генә тора. Аңа ничек тә Караболакка кайтып өлгерергә кирәк, кайтып Караболак туфрагына аварга, аны кочарга. Нинди булса да, Гөлҗиһан өчен ул иң газиз җир, туган туфрак...

## Егерме беренче бүлек

Поезд, бөтен көченә томырылып, Урал таулары арасыннан аргы якка чаба.

Аргы якта — Чиләбе далалары, диңгездәй күлләр, шул күл буйларына урнашкан татар авыллары...

Биредә — тау да урман, тау да таш. Каршыга, йөгереп, әле кыя-ташлар чыгып баса, әле тау елгалары атылып чыга. Ике якта да, дәрья кебек дулкынланып, тау сыртлары тезелеп киткән. Урал тауларына күпме караса да, карап туя алмый Гөлҗиһан. Ул аларны әллә нинди эчке тетрәнү, олылау белән ярата. Чөнки алар аның Алып бабаларының Төп Йорты булган. Алар шуннан бөтен дөньяга таралганнар. Менә бу тау сыртларында аларның аяк эзләре уелып калган, кыяташларда кул тамгалары ярылып ята. Болар барысы да — Гөлҗиһанның туган җирләре, борынгы бабаларының илләре, татарлар ил-дәүләт тоткан урыннар.

Ә хәзер бу тау араларын җимерек урыс шәһәрләре басып киткән.

Бөтен җирдә — чәнечкеле тимерчыбык, тырпаеп торган сак каланчалары, җир эченә кереп киткән тимер юллар. Тау аралары, тау аслары тулы атом объектлары, корал саклау урыннары, хәрби базалар. Бирегә кош та үтеп керә алмый, керсә, кире чыга алмый. Бөтен Урал тауларына җәелеп, җир асларында атом заводлары эшләп ята, дөньяда тиңе булмаган үлем кораллары җитештерелә. Кайда урыс хәрбиләре аяк баскан — анда җир яна, җир көя, тормыш бетә. Анда үлем, анда җимереклек, анда җинаять. Бу халык үзләре бе-

лән бергә башкаларны да упкынга өстери. Матурлыкны үтерә. Менә Урал таулары да, урыс шәһәрләре һәм хәрби базалар булган урыннар да янып, көеп ята. Анда үлән дә юк, агач та калмаган, яшәү дә бетеп бара. Инде таш булып таш бу яәҗүҗ-мәәҗүҗ кавеменә чыдамагач, кеше ничек чыдасын? Алар кул астында яшәргә мәҗбүр ителгән татар нишләсен?

Гөлҗиһан, коридорга чыгып, поезд тәрәзәсеннән әнә шуларны карап бара. Ул хәзер дөньяга бөтенләй башка төрле карый. Аның инде бөтен сорауларга да җавабы бар...

Милләте бу яәҗүҗ-мәәҗүҗ кавеме артыннан, аңа ияреп барса, харап булачак. Хәзер бөтен яктан алардан аерылырга, алардан читләшергә кирәк — телдә дә, диндә дә, яшәү рәвешендә дә, тормыш алып баруда да, дөньяга караштa да. Чит кануннар йөрми торган үз илеңне булдыру кирәк. Беркем дә синең өеңә килеп атом төтене белән агуларлык булмасын, синең җирләреңдә үлем базлары ясарлык булмасын, синең телеңә, динеңә, тормышыңа хуҗа булырлык булмасын. Татарның үз иле, дәүләте булмаса, ул һәрвакыт башкаларның тәҗрибә корбаны булачак. Чөнки Татар Караболагы тарихы — ул бөтен милләт тарихы, татар халкының фаҗигасе. Исән калган татарлар инде моннан да гыйбрәт алмаса, аларның барысын да Татар Караболагы язмышы көтә.

Ул арада әллә берәр купедан, әллә поезд радиосыннан үзәк өзгеч моң агыла башлады. Бу — татарча җыр иде. Гөлҗиһаннар турында, Караболак татарлары хакында, татар халкы турында җыр иде. Моны ишеткәч, Гөлҗиһанның бөтен тәне калтырап китте, күзләренә яшь бәреп чыкты. Ул маңгае белән тәрәзәгә капланды, җаны белән җырга каршы йөгерде.

Хуш, Чиләбе кала, сахра-дала,  
Күккә тиеп тора Урал-тау.  
Сау булыгыз, дуслар, без китәбез,  
Бәлки, очрашмабыз исән-сау...

Гөлҗиһанның күз алдыннан Караболакны ташлап чыгып китәргә мәҗбүр булган авылдашлары тезелешеп үтеп киткән кебек булды. Атом афәте аларны дөнья буйлап куды, дөнья буйлап таратты. Алар үләргә генә, үлгәч кенә Караболакка кайттылар. Инде мәңгегә шунда ятып калу өчен кайттылар.

Хуш, Чиләбе кала, сахра-дала,  
Күккә тиеп тора манара.  
Сау булыгыз, дуслар, без китәбез,  
Бәлки, очрашмабыз тиз ара...

Гөлҗиһанның каршына, тезелешеп, бу дөньядан инде мәңгегә киткәннәр килә. Әнә картнәе аңа догалар өйрәтә. Карттае аңа чана ясый. Әтисе аңа үзенең киңәшләрен бирә. Әнисе кочагында тибрәтә. Фәргате кулларына күтәреп йөртә. Улы Баһадур битләреннән үбә. Энеләре аның кулларыннан килеп җитәкли. Рәшидә үзенең бәетен укый. Рабига дога кыла. Таифә, Җәүһәрия түтиләр теләк тели. Инде бөтен Урал таулары кеше белән, Караболак халкы белән тула, ә алар һаман киләләр дә киләләр...

Хуш, Чиләбе кала, сахра-дала,
Елкылары чыккан бәйгегә.
Сау булыгыз, дуслар, без китәбез,
Бәлки, очрашмабыз мәңгегә...

Гөлҗиһан, поезд тәрәзәсенә капланып, үксеп елый башлый...

Әйтерсең лә ул шушы урман-тауларны, сахра-далаларны соңгы тапкыр күрә. Алар белән мәңгегә хушлаша, мәңгегә бәхилләшә. Үзе дә алардан мәңгегә китеп бара. Бу чыннан да шулай иде...

Поездан төшүгә, Гөлҗиһан автобуска утырды, аннан Караболак турында олы юлда төшеп калды. Бу араны ул инде шактый күп җәяү йөрде, бу юлы да шулай туры килде. Гөлҗиһанның йөге авыр түгел иде, шуңа күрә ул әкрен генә җәяүләп атлады. Ул бу юлның һәр борылышын, һәр ташын, һәр чокырын белә. Гөлҗиһан алар белән дә беренче тапкыр күргәндәй очраша һәм соңгы тапкыр күргән кебек хушлаша. Колагында һаман теге җыр:

Сау булыгыз, дуслар, без китәбез,
Бәлки, очрашмабыз мәңгегә...

Гөлҗиһан туп-туры Таһирҗан бабайларга китте.

Таһирҗан карт берьялгызы урын өстендә ята иде. Башта Гөлҗиһан аны танымыйча торды — Таһирҗан бабайның чәчләре яңадан ап-ак булган, сакалы агарган, йөзе дә агарып, озынаеп калган. Күренеп тора, Таһирҗан бабай соңгы көннәренә кергән иде. Ул Гөлҗиһанга башын калкытып карады, әмма урыныннан тора алмады. Гөлҗиһан тиз генә чәй куеп җибәрде, өйләрне җыештырып чыгарды, тәрәзәләрне ачып, һаваны алыштырды. Авырлык белән булса да бабасы чәй эчәргә торды, өстәл янына үзе килеп утырды.

— Бабай, ашыйсың килгән берәр нәрсәң юкмы соң, әзерләрмен? — диде Гөлҗиһан.

— Аллакүл чишмәсенең суын эчәсем килә, кызым, — диде Таһирҗан карт, бераз тын яткач. — Шуны өшкереп бирсәң, хәлем җиңеләер кебек...

Өйдә чишмә суы беткән иде. Гөлҗиһан, савыт алып, Аллакүл чишмәсенә чыгып йөгерде.

Бераз шулай кызу баруга, аның тыны бетте, күз аллары караңгыланды, йөрәге шашып тибә башлады. Гөлҗиһан тизрәк юл читендәге ташка барып утырды, бераз хәл җыйды. Аннан тагы китте. Шулай бер утырып, бер басып дигәндәй, ул Аллакүл чишмәсенә барып җитте. Барып җитүгә, салкын су белән бит-кулларын юды, кушучлап чишмә суы эчте. Тәненә тагы җан керде, көч-куәте кире кайтты. Ул Әбиташка аркасын терәп утырды һәм күзләрен йомды. Ул үзенең шушында үткән бөтен гомерен күрде, әйтерсең лә Гөлҗиһан бирегә барысы белән дә бәхилләшергә килгән иде. Әнә аның каршына ут борчасы кебек нәни кызчык йөгереп килә. Бу — Гөлҗиһан үзе, аның кечкенә чагы. Ул шундый тере, чая, бәхетле, аны дөньяда бернинди авыру да, бернинди авырлык та алмас кебек. Әнә ул Алып Адәм ташына менеп баскан да күл буйларын яңгыратып шигырь укый:

Әй, милләтнең сылу балалары,
Дөнья тетрәткән Хан бабалары.
Ханыңны, барча гаскәреңне
Дошманнар узып китте,
Куәтле чакларың кайларга китте?

Әнә Таһирҗан бабасы аңа Алып татарлар, аларның тарихлары турында сөйли. Әнә алар биредә Фәргать белән беренче намазларын укыйлар, Аллаһтан бала сорыйлар. Әнә биредә аларның балаларының аяк эзләре уелып калган. Әнә Аллакүл. Әнә яр буйларындагы серле зәңгәр балчык. Әнә беренче кешеләрне үзенә сыендырган тау куышы. Алып Адәм намаз укыган борынгы таш. Әнә янәшәдә генә борынгы курганнар, каберлекләр. Әнә Караболак... Барысы да кала... Гөлҗиһан да инде алардан мәңгелеккә китә. Ул бирегә алар белән бәхилләшү өчен дә килде. Таһирҗан картның һәм үзенең соңгы теләген үтәү өчен...

Алып килгән савытларына чишмә суы тутырды да Гөлҗиһан, кайтырга чыкты. Аллакүл аны моңсу гына озатып калды. Бу аның Гөлҗиһанны соңгы тапкыр күрүе иде. Гөлҗиһан да бу серле күл белән соңгы тапкыр очраша иде...

Әллә эчкән суларының файдасы тиде, әллә бераз ял итеп алуы ярдәм итте, Гөлҗиһан авылга тиз кайтып җитте. Таһирҗан карт аны ишеккә карап көтеп ята иде. Гөлҗиһан үзе белгән догалар белән, Коръән аятьләрен укып, чишмә суын өшкерде һәм бабасына бирде. Таһирҗан карт, бисмилласын әйтеп, аны бер-ике йотты да, күзен йомып, урынына сузылып

ятты. Ул шулай шактый вакыт тын гына ятты. Гөлҗиһан куркып аның өстенә иелде, кулларын тотып карады. Аларда сизелер-сизелмәс кенә җылылык бар иде. Бераз яткач, карт күзләрен ачты.

— Мин китәм инде, кызым, — диде ул, бик ерактан килгән тонык тавыш белән. — Бу дөньяда ике теләгем калган иде. Берсе — сине күрү, икенчесе — Аллакүл чишмәсенең суын эчү. Рәхмәт сиңа, теләгемне үтәдең.

Шулай диде дә Таһирҗан карт, бераз тын ятты. Аның күз алдыннан бөтен гомере йөзеп үтеп китте... Яшьли дөньядан киткән хатыны, берәм-берәм үлеп беткән балалары, оныклары. Авыл халкы белән бергә күргән шатлык һәм кайгылары. Газап һәм өметләре. Ул, җеназа укып, үз куллары белән ике меңнән артык авылдашын Караболак зиратына күмде. Хәзер инде менә үзенә дә чират җитте. Барысына да чират җитте, әмма монысын халык белми әле... Җаннарны алырга төшеп килгән күк тулы фәрештәләрне дә күрмиләр. Алар һәркемгә күренмиләр шул.

— Мин синнән бәхил, кызым, син дә бәхил бул, — диде Таһирҗан карт, бераз тын яткач. — Һәм әзерлән... Алар инде төшеп киләләр... Курыкма. Аллаһ безне җәннәттә күрештерсен, кызым... Ләә-илаһә иллаллаһ... Ләә-илаһә иллаллаһ... Ләә-илаһә иллаллаһ...

Карт берничә тапкыр шаһәдәт кәлимәсен әйтте дә, нәрсәгәдер бик нык сөенгәндәй, елмаеп куйды. Аның йөзе яктырып, нурланып китте, ул сөйләшеп яткан җиреннән әкрен генә күзләрен йомды. Ул аларны инде мәңге ачмаска йомган иде...

— Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигуун...

Шул сүзләрне әйтеп, Гөлҗиһан бабасының битеннән сыпырды. Кулларын гәүдәсе буенча сузып салды...

Нәселнең соңгы акыл иясе, әүлиядай изге зат бу дөньядан икенчесенә күчкән иде. Ул бөтенесенә дә алдан әзерләнгән — өстендә чиста күлмәк-ыштан, тырнак-төкләре киселгән, үзеннән тәмле исләр килеп тора, ул әйтерсең үлмәгән, кунакка барып кайтырга гына җыенган. Гөлҗиһан үзенең кайтып җитүенә, бабасының соңгы теләген үти алуына сөенде. Бәлки, карт аны җаны белән шулай чакырып кайтаргандыр, төшләре аша хәлен белгерткәндер. Ул гади кеше түгел иде бит. Бабасы ялгыз йортта үлмәде, соңгы теләге үтәлеп, бәхиллеген биреп, шаһәдәт кәлимәсен әйтеп, иман белән җан бирде. Җиңел китте. Картның үлеме дә изгеләрчә, җиңелләрдән булды. Инде урыны да оҗмахта булсын, Раббым.

Икенче көнне Таһирҗан картны бөтен авыл белән күм-

деләр. Бу хәбәрне ишетеп, читтән кайтып җитүчеләр дә булды, карт белән хушлашырга күрше авыллар да килде. Таһирҗан картның үлүенә ышанасы да килмәде, ул мәңге шулай Караболак урамнары буенча тын гына йөрер кебек тоела иде. Аның беркайчан да авырып урын өстендә ятканы булмады, зарланмады, киресенчә, яшәргәннән-яшәрә барды. Һәм сәламәт килеш китеп тә барды. Ә авыл калды. Мең хәсрәте, мең кайгысы, чир-хасталары белән Караболак Таһирҗан картсыз утырып калды. Авыл догачысын югалтты. Караболак үзе дә Таһирҗан карт артыннан мәңгелеккә китәргә әзерләнә иде. Зәңгәр күкне тутырып, Урал тауларына әҗәл фәрештәләре төшеп килә иде. Әмма аларны күрү сәләте һәркемгә дә бирелмәгән иде...

Таһирҗан бабасын күмгәннән соң, Гөлҗиһан үз өенә кайтты. Буш йортка килеп кергәч, ул беренче эш итеп, намазын укыды.

Әти-әнисе, әби-бабалары, Таһирҗан бабай, ире Фәргать, улы Баһадур, бөтен туганнары рухына багышлап, озаклап дога кылды. Күңеле бераз тынычланып киткән кебек булса да, тән сызлаулары басылмады. Эчендә бертуктамый авыру сулкылдап ята, дару эчкәч тә җибәрми. Гөлҗиһан, соңгы көчен җыеп, Аллакүл чишмәсенең суын өшкереп эчте, эчке януы бераз басылган кебек булды. Аннан чиста киемнәрен алып киде, башына ак яулыгын бәйләде. Тәрәзәдән килеп, Караболак урамына карады. Караболак та төнгә кереп килә иде. Соңгы төненә...

Караболак урманнары артында Иртәш утлары шәйләнә, шәһәр өстендә күк йөзе яктырып, янып тора. Тиздән бу яктылыкны икенче ут алыштырыр. Әмма шәһәрдә әле бу хакта белмиләр, күк тутырып төшеп килгән әҗәл фәрештәләрен дә күрмиләр. Чөнки аларны күрү сәләте һәркемгә дә бирелмәгән.

Иртәштә Гөлҗиһанның кайтып керүен көтәләр. Аның турында хәбәр Мәскәүдән тиешле органнарга килеп җиткән инде. Бу белешмәләрдә Гөлҗиһан җәмгыять өчен куркыныч кеше, фетнә чыгаручы, дәүләт серләрен ачучы, дәүләт иминлегенә янаучы, чиктән ашкан татар милләтчесе, терроризмга сәләтле мөселман фанатигы итеп сурәтләнгән иде. Һәм мәскәүләрнең уй-фикерләре иртәшнекеләр белән туры килә иде. Аның гарәп илләре белән элемтәдә торуы да, балаларын шунда җибәрүе дә, Караболакта чакта чеченнар белән аралашып ятуы да, намаз укуы да аларга билгеле иде. Шушы гаепләүләрнең берсе генә дә Гөлҗиһанны гомерлек төрмәгә тыгарга җитә иде, яки мәңгелеккә җүләрләр йортына

ябарга. Һәм аны кулга алу өчен, Иртәшкә кайтып керүен генә көтеп торалар иде. Ткаченко командасы җиң сызганып эшкә кереште. Болар барысы да терроризмга каршы көрәш битлеге астында эшләнә иде.

Ә Гөлҗиһан болар турында әле белми иде. Ул, кыйблага карап, озаклап төнге намазын укыды. Намаздан соң, сәҗдәләргә китеп, озаклап догасын кылды. Намазлык өстенә кайнар күз яшьләре тамды.

Әйтерсең лә яңа туган сабый ак биләвендә шулай елап ята…

Бу сабый — Гөлҗиһан үзе бит, әнә ап-ак куллар аны югарыга күтәреп алып менеп китәләр. Бу — әти-әнисенең көчле куллары икән. Алар яңа туган кызларын бөтен дөньяга күрсәтәләр. Юк, бу — фәрештәләрнең ак канатлары бит. Алар аны әнә Караболак өстенә алып менеп баралар. Аста әти-әнисе, әби-бабасы, бөтен туганнары, бөтен балалары, бөтен Караболак халкы, кул болгап, озатып калалар. Алар барысы да шундый яшьләр, матурлар, көчлеләр. Аннан алар юкка чыга. Шулчак Гөлҗиһан алдында бөтен дөнья яктырып китә, күк капкалары, ачылып, аңа юл бирә. Гөлҗиһан, кулларын канат итеп җәеп, шул яктылыкка таба оча. Алда аны нурлы болын көтә, улы Баһадур, нәни кулларын сузып, аның каршына йөгерә. Аның күз алдында соңгы тапкыр күк капусы ачыла, ул, соңгы кеше булып, шул капкалардан кереп югала, нурлы болынга чыгып өлгерә. Анда аны улы, ире, әтиәниләре, әби-бабалары, туганнары, авылдашлары көтеп тора. Мәңге авырулар булмый торган, мәңге бәхет дөньясы көтә…

Җиһанның соңгы бәхет капкалары ябыла. Һәм Иртәш өстенә күктән утлы ташлар ява башлый…

Һәм…

Урал таулары тетелеп күккә оча. Иртәш суы ташып ярларыннан чыга.

Җир үз өстендәге бөтен нәрсәне тышка чыгарып ташлый. Таш йортлар комга әйләнә, ком көл булып күккә оча…

Ата — баланы, бала ананы күрми, һәркем үзен коткарырга тырыша. Җир уты белән күк уты бергә кушылып, шәһәрне юк итә…

Кешеләрдән кара күләгәләр генә торып кала…

Ил өстенә атом афәте тарала…

Һәм Аллаһы Тәгалә әйтте:
— Сезгә ирешкән бәла-казалар вә кайгылар
үзегез кәсеп иткән гөнаһларыгыз сәбәпле.

Һәм Аллаһы Тәгалә әйтте:

— Үткән өммәтләрдән күпме өммәтне Без һәлак иттек,
алар исә һәлакәт килгәндә кычкырдылар,
аларга ошбу вакыт котылмак, качмак вакыт түгел, дидек.

Һәм Аллаһы Тәгалә әйтте:
— Аларның өстенә яңгыр урынына таш яудырдык.
Куркытып та курыкмаган кавемнәрнең яңгыры
нинди яман яңгырдыр...

Һәм Аллаһы Тәгалә әйтте:
— Һәм аларны һәлак итүдә Без берсен икенчесенә ияртте́к,
үзләрен һәлак итеп,
сөйләргә хикәяләрен генә калдырдык.
Аллаһының рәхмәтеннән еракльк
ышанмаган кешеләргәдер...

Бу — бөтен дөнья өчен иң зур кисәтү, кешелек өчен соңгы кисәтү иде...


СОҢҒЫ
НАМАЗ

**«Алар, Аллаһ биргән белемне хак юлга кулланмыйча, һәлак булдылар».**

***Коръән, «Үрмәкүч» сүрәсе, 38 нче аять***

***Өстә — зәңгәр күк, аста — кара җир, уртада — кеше иде...***

***Башта күкләр хәрәкәткә килде...***
***Бөек әмер белән саф тезелде...***
***Аннан алар рәт-рәт булып җиргә иңде...***
***Җиһанның Хәтер Китабы телгә килде...***
***Аннан Җир-Су хәрәкәткә килде...***
***Күкләр сораганны — Күккә бирде...***
***Җирдә каласыны — Җиргә бирде...***
***Җиһанның Хәтер Китабы телгә килде...***

***Өстә — зәңгәр күк, аста — кара җир, уртада — кеше иде...***

Караңгы август төне иде...

Кичтән үк давыллап-җилләп торды, шәһәр өстен хәзер дә авыр кара болытлар каплап киткән. Болытларның авырлыгыннан һәм якынлыгыннан биек таш йортлар да кечерәеп һәм чүгеп калганнар кебек. Соңгы вакытта җил-давыллар күп бәла-казалар китергәнлектән, шәһәр халкы бу төнгә дә әллә нинди хәвеф һәм шом белән керде. Урамнар гадәттәгедән иртә бушап калды, сүнәсе утлар сүнде, шәһәргә хуҗа булып кара төн килде. Кара төнгә ияреп, шомлы хәбәр килде. Башта, төнге тынлыкны телгәләп, этләр улый башлады... Күккә карап, бала елаган тавышлар чыгарып, үксеп-үксеп уладылар алар... Әйтерсең лә алар күк йөзендә адәми зат күрмәгәннәрне күрә иде. Шушы тетрәндергеч илаһи күренеш урам этләрен җирләрне тырный-тырный үксергә, еларга, ялварырга мәҗбүр итә иде. Эт улаган тавышка йорт почмакларыннан, өй асларыннан мәчеләр атылып чыкты, алар, шашынган кебек, этләрне бәрә-ега, бу таш тауларыннан ераграк йөгерделәр... Аннан, җепкә тезелгән кебек, йорт асларыннан күсе-тычканнар чыга башлады. Алар да йортны ташлап качты... Аннан йорттагы барлык бөҗәкләр — чикерткә-

ләр, тараканнар хәрәкәткә килде, алар да, тизелешеп, стеналар буйлап шуышып, җиргә үрмәлиләр, җиргә сыенып качып калырга тырышалар иде... Кешедән кала, барлык җан иясе хәрәкәткә килеп, һәлакәттән качарга омтыла иде... Адәм баласы үзенең күрәчәгеннән бихәбәр иде, адәм баласы төнге йокысына, соңгы йокысына әзерләнә иде...

Йорт төнгә керде...

Үзенең исерекләрен һәм аекларын алып, намаз укучылары һәм динсезләре белән, яңа байлары һәм ач-хәерчеләре белән, зиначылары, наркоманнары, күрәзәче-сихерчеләре белән Йорт дөньялыкның соңгы әйләнешенә килеп керде. Әмма моның соңгы төн икәнен йорттагылардан беркем дә белми иде...

Инде ярты төн җитүгә карамастан, әле берничә тәрәзәдә ут яна — кемдер төнгә каршы соңгы намазын укый, кемдер бикләнеп эчә, кемдер яшеренеп зина кыла, кемдер сихер ясый, кемдер, җанына урын таба алмыйча, таш тозагында бәргәләнә иде...

* * *

Мәрьям ана да *соңгы намазына* — төнге намазына әзерләнә.

Тулы исеме Мәрьямбану аның. Дингә килгәч, кемдер зурлап, кемдер хурлап Мәрьям ана дип атый башладылар. Мәрьямбану аларның берсенә дә үпкәләми. Марьямбануда хәзер бер генә уй — улы турында. Менә инде елга якын ул аның хакында берни дә белми яши иде. Бүген көндез телевизордан улының дустын — күрше егете Хәйдәрне күрсәттеләр. Имеш, ул чечен әсирлегендә булган, имеш, шунда татар егетләрен дә күргән... Дөрес, Хәйдәр үзе телевизордан артыгын сөйләмәде, башын куллары белән тотып, читкә карап тик утырды. Аның урынына ниндидер хәрби сөйләде. Имеш, чеченнар үзләренә ярдәмгә килгән утыз сигез мөселман-татар егетен атканнар икән! Аларны Россиягә эшләүдә, хыянәттә гаепләгәннәр. Шушы сүзләрне ишеткәч, Мәрьямбану баскан урынында чайкалып куйды. Чеченнар татарларны атканнар? Булмас, була торган хәл түгел бу. Мәскәү, һәрвакыттагыча, ялганлыйдыр, ничек инде җиһадка дип килгән мөселманнарны мөселманнар үтерергә мөмкин?! Аллаһы Тәгалә моңа ирек бирмәс. Мәскәү бу куркыныч хәбәрне махсус таратадыр, мөселманнарны үзара сугыштырырга, татар белән чеченны ызгыштырырга телидер...

Мәрьямбану телевизордан ишеткән һәр сүз белән әнә шулай бәхәсләшеп, ризалашмыйча барды. Үзе, өметләнеп, Хәй-

дәргә карады, бу хәрби кешегә каршы әйтүен көтте, әмма Хәйдәр дәшмәде. Бары тик: «Атылган татарлар арасында танышларыгыз бар идеме?» — дигән сораута: «Күрше егете бар иде», — дип җавап бирде. Мәрьямбану тынсыз калды, ишек яңагына ябышты, кипкән иреннәре «юк, юк...» дип пышылдады. Булмас... Мөселман мөселманны үтермәс... Аның улын мөселманнар үтермәс! Бу — дөньяда була торган хәл түгел...

Әмма бу илдә барысы да булырга мөмкин иде...

Мәрьямбану моңа кадәр дә Чечняга киткән татар егетләре турында төрле хәбәрләр ишеткәләде инде. Имеш, ФСБга эшләгәннәр икән, имеш, шуның өчен чеченнар аларны әсирлектә тоталар икән... Бу хәбәрләр берсе дә Мәрьямбануның улына кагылмый иде, чөнки ана үз баласының пакьлеген һәм хаклыгын яхшы белә иде, шуңа күрә нәрсә генә ишетсә дә, нык торды, сер бирмәде. Ә менә бүген аяк астыннан җир китте, өстенә күк ишелеп төшкән кебек булды, ул, кайгысын эчкә йотып, Аллаһтан сабырлык сорады, сабырлык сорады... Әгәр бу сүзләрне Хәйдәр әйтмәсә, Мәрьямбану Мәскәү сүзләренә игътибар да итмәс иде. Хәйдәр бит улының балачак дусты, мәдрәсәдә укып йөргән егет, Чечняда да беренче генә булуы түгел... Дөрес, ул соңгы вакытта милиция мәктәбендә укып йөрде, аның кемгә хезмәт иткәнен бер Аллаһ кына белә... Әгәр аның улы Әхмәт белән Чечняда нидер булган икән, нигә Хәйдәр беренче эш итеп ул хәбәрне аңа җиткермәгән? Хәйдәр бит соңгы китүендә Чечняга ОМОН отрядлары белән китте, димәк, классташы Әхмәт белән дә ул бары тик яу кырында гына очраша ала? Мәрьямбануның тәне тагы эссе-ле-суыклы булып китте — йа Хода, бер йортта яшәгән, бер класста, бер парта артында утырып укыган ике татар егете ни өчен Каф тауларында бер-берләренә каршы корал тотып басарга тиеш иде соң?! Нигә? Нәрсә хакына, кем өчен?!

Мәрьямбануның башында мең төрле уй, мең төрле шикшөбһә кайный иде. Ул кичекмәстән Хәйдәр янына кереп чыгарга уйлады. Аның бу сорауларына бары тик Хәйдәр генә ачыклык кертә ала иде. Мәрьямбану ашыгып ишеккә атлады. Телефонның кисәк чәрелдәп җибәрүеннән бөтен тәнен, миен, күзәнәкләрен ток тоткандай булды. Кул-аяклары шундук хәлсезләнеп китте. Башына: «Бәлки, Хәйдәр үзе шалтыратадыр?» — дигән уй килде. Әмма телефонда Хәйдәр түгел иде. Тагы шул бәндә... Улы киткәннән бирле, һәр көнне диярлек кичке якта шалтыратып, ялгыз ананың җанын актара, еландай юха тавышы белән һаман аның күңеленә шуыша, һаман нидер эзләнә...

Менә ничә еллар буе бу кеше кара шәүлә булып Мәрьямбануның артыннан килә, күзләре белән дә, сүзләре белән дә эзәрлекли, кайгы-хәсрәт булып язмышына урала...

— Улыгыздан бер-бер хәбәр юкмы, Мәрьям ханым?

Башка көннәрне Мәрьямбану, сүзне бик озайтмыйча, «юк» дип кенә трубканы куя иде. Бу юлы алай итә алмады. Ул моңа кадәр улы турында, кем сораса да, чит илдә укуда, дип әйтә иде. Әмма органнардан дөресен яшереп буламы соң? Алар аның улы турында Мәрьямбануның үзеннән дә күбрәк беләләр иде, ахры... Бу кеше — бигрәк тә... Исеме дә «шайтан» дигәнне аңлата бит аның — Хәррис. Мәрьямбану сизә бит, сизә — эштән җибәрелүендә дә, гаиләсе җимерелүдә дә, хәтта ире Тимербулатның өйдән чыгып китүендә дә бу кешенең катнашы булырга тиеш. Улы Әхмәтнең язмышында да бу кара кешенең кулы уйнадымы икәнни? Ярый, Мәрьямбануга, Тимербулатка ачуы, үче дә булсын, ди, ә бу яшь баланың язмышы белән нигә уйный ул? Нигә чама дигән нәрсәне белеп, туктый алмый?

— Минем улым турында сездә хәбәр булырга тиеш. Нигә аны миннән яшерәсез?

Телефонның теге башындагы тавыш сагаеп калды:

— Сез бүген телевизордан булган хәбәрне әйтәсезме?

Инде хәзер Мәрьямбану сагайды. «Әйе» дисә, улының кайда икәнлеген үз теле белән раслаячак, «юк» дисә, баласы турында нинди дә булса хәбәр белергә теләү аны инде өзгәли, газаплый башлаган иде.

Ана дәшмәде... Юха тавыш үзе ярдәмгә килеп, өстәмә сорау бирде:

— Мәрьям ханым, сез улыгызның дусты Хәйдәр белән очраштыгызмы әле?

— Юк, минем беркем белән дә очрашканым юк.

— Сез, алайса, очрашырга ашыкмагыз әле... Бәлки, үзем яныгызга кагылып чыгармын... Барысын да сөйләшербез...

Мәрьямбану «юк» дип әйтергә өлгермәде, Хәррис трубканы куйган иде инде. Мәрьямбану тагы аптырашта калды. Ни өчен бу кешене аның Хәйдәр белән очрашу-очрашмавы кызыксындыра? Нигә очраштырырга теләми? Әгәр телевизордан әйткәннәр хак булса, аларга хәзер барыбер түгелмени инде?

Телевизордан әйткәннәр хак булса... Мәрьямбану үз уеннан үзе куркып китте. Ул бу сүзләрнең дөрес булмавын тели. Бу куркыныч хәбәрнең дөресме-түгелме икәнен бары тик Хәйдәр генә раслый ала иде.

Телефон янында гасабиланып утырган ана кинәт кенә яңа фикергә килде. Тукта, ул бит Хәйдәр белән телефоннан да сөйләшә ала! Башта өйдәме-юкмы икәнен белер, аннан очрашып сөйләшерләр. Бу кадәр зур сүзне, бу кадәр кайгылы хәлләрне ишек төбендә, аяк өсте генә сөйләшеп булмас, башта шалтыратып хәбәр бирсен, әзерләсен... Ул да балалы-

гыннан чыгып җитмәгән бит әле, ә нинди канлы фаҗигаләргә барып керде... Бу татар егетләренең язмышында әгәр аның да катнашы, гаебе булса?..

Ләкин Хәйдәрнең телефоны җавап бирмәде. Озак шалтыратты Мәрьямбану, озын гудок араларында йөрәген учларына кысып, сызлана-сызлана көтте. Бу дөньяда улы турында бары бер дөрес хәбәр көтте. Ул инде «үлгән» дигән хәбәрне ишетергә дә әзер иде, тик чеченнар тарафыннан гына үтерелгән булмасын. Монысын ишетергә, кабул итәргә, аңларга Мәрьямбану әзер дә, риза да түгел иде. Мөселман улының мөселманнар тарафыннан үтерелүенә Мәрьямбану ананың бөтен җаны-тәне елап, әрнеп, рәнҗеп каршы торды...

Чечняга китәргә җыенганын улы аңа әйтте. Башта Мәрьямбану каушап китте, улының җиһадка әзер мөселман ир-егете булып өлгереп җитүенә бер куанып горурланса, ахырын уйлап, кинәт кенә боегып, кайгырып калды. Әнисенең күңелендә мең төрле уйлар кисешүен, чарпалануын сизеп, улы аны иплəп кенә иңнәреннән алды, каршына алып килеп утыртты.

— Нигә борчыласың, әни? — дип сорады.

Мәрьямбану, ни әйтергә дә белмичә, мөлдерәп, улына карады. Бер яктан, Коръән буенча, мөселман кешесе дин өчен изге сугышка — җиһадка барырга тиеш, мөселманнарны яклап сугышу — аның өчен фарыз, мәҗбүри шарт. Икенче яктан — ул бит аның бердәнбер улы, карап торганы, ничекләр итеп шул баланны үз теләгең белән үлемгә чыгарып җибәрергә? Әллә кайда, әллә кемнәр арасында барган сугыш өчен...

— Улым, бу чечен сугышы элеккесенә охшамаган бит, — дип башлап карады ул сүзен иплəп кенә. — Кем өчен, нәрсә өчен сугышканнарын да аңлап бетереп булмый. Җитмәсә, Дагестанга барып керделәр, хәзер үзара мәңгелек дошман булып калдылар. Шушы янып торган утка татар егетләре дә барып керсә, моннан кемгә файда булыр соң? Анда китеп барыгыз да үлеп бетсәгез, монда милләт өчен, дин өчен кем көрәшер?

Кереш сүз озакка китте. Әмма улының җавабы бик кыска булды:

— Әни, мин сине тыңлыйммы, Аллаһы Тәгаләне тыңлыйммы?

Ана сүзсез калды. Җавап билгеле иде. Улы аны кочаклап алып юатырга тырышты:

— Без анда үләргә дип китмибез, әни! Мөселманнарга ярдәм итәргә барабыз. Анда Мәскәү нәрсә сөйли — аларның эше. Син догада бул, әни, фатихаңны бир... Шәһит китсәм, Җәннәттә очрашырбыз...

Мәрьямбану фатихасын бирде. Үз теләге белән бердәнбер улын сугышка чыгарып җибәрде. Ана кеше бердәнбер баласын мөҗәһидлек үлеменә — мәңгелек Җәннәткә озатты...

Әйе, улын Чечняга үз теләге, үз ихтыяры белән чыгарып җибәргән иде Мәрьямбану. Чөнки Аллаһының әмере шулай иде. Ана улын Аллаһка тапшырды, үзенә исә бу ачы сынауларга түзә алырлык сабырлыклар сорады, сабырлыклар ялварды...

Сабырлыклар сорады, әмма көндезге хәбәрне ишеткәннән соң, бөтен эче яна Мәрьямбануның. Авыр итеп тын ала да, тагы Аллаһтан сабырлык сорый, ыңгырашып куя да, «балам, бәгърем» дип пышылдый. Чеченнарга ярдәм итәм, дип чыгып китеп, чеченнар үтергән булса, моны Мәрьямбану кичерә алмаячак. Хәтта үз-үзен дә... Ул бит аның карап торган бердәнбере иде. Алар егерме ел буе бер тән, бер җан, бер сулыш, бер тормыш булып яшәделәр. Бер-берләренең хәлләрен тын алуларыннан, күз карашларыннан аңлыйлар иде. Бер тапкыр хәтер калдырырлык итеп дәшкәннәре, сөйләшкәннәре булмады, хәтта бер-берләренә тавышларын да күтәрмәделәр. Авырлыклар килгәндә, ана — улына, бала анасына сиздермәскә тырыштылар. Ә бит тормышларында авыр вакытлар күп булды аларның, кимсетелгән, каһәрләнгән чаклары да булды. Бигрәк тә Ләйлә мәсьәләсендә төрле сүзләр ишеттерделәр, кызның ата-анасы балаларын Әхмәттән аеру өчен нәрсәләр генә эшләп карамады. Шуңа күрә Чечняга чыгып киткәндә дә, Әхмәтнең соңгы сүзләре Ләйлә турында булды:

— Әни, Ләйләне ташлама инде син. Аларның өендә... үзең беләсең бит, дин тотучы да юк...

Ләйлә турында әйтте дә кызарып чыкты.

— Кызым кебек булыр, балам, борчылма. Ичмасам, өйләнә дә алмыйча калдың бит. Кавышырга ирек бирмәделәр...

— Насыйп булса, кавышырбыз, әни. Монда булмаса, Җәннәттә кавышырбыз... Җәннәттә очрашырбыз...

Әхмәтнең соңгы сүзләре шул булды. «Җир кешесе өчен ул Җәннәтләргә юл бик ерак, бик авыр шул, улым... Җәннәткә юл җәһәннәмнәр аша үтә... Җирдәге тормыш үзе дә хәзер утлы җәһәннәмгә әйләнеп бара. Кеше үз-үзенә дә, берберенә дә дошман, ачулы, үчле». Менә хәзер дә йөгереп Ләйлә янына керер иде, кысып-кысып кочаклап елар иде, җанын юатыр иде... Ул да мөмкин түгел, чөнки Ләйләне әнисе тагы психбольницага салган. Йа Хода, дин тоткан, яулык бөркәнгән өчен генә, аларча киенмәгән, аларча ашамаган, аларча яшәмәгән өчен генә ана кеше үз баласын юләрләр йортына салсын инде?! Заман ахыры шушы буладыр инде...

Алай да, йөрәге түзмәде, Ләйләләрнең өенә шалтыратып карарга булды. Озак кына көттергәннән соң, җавап бирде-

ләр. Әнисе... Хәзер кычкырырга, талашырга тотыныр инде. Ничек тә түзәргә, Ләйлә турында бер-бер хәбәр белергә кирәк.

— Кем кирәк?!

— Бу Мәрьямбану иде... Ләйләнең хәлен белим дигән идем.

— Сиңа бу йортка шалтыратмаска дип әйтелде бит инде! Сихерче! Кызымның башына сез җиттегез, фанатик улың белән бергә! Малаеңа каратыр өчен дин белән сихерләдең! Мин сезне чиста суга чыгарам әле! Ваһһабичылар! Сектантлар! Мин сезнең кем икәнегезне бөтен дөньяга җиткерәм!

Башка тыңлап торудан мәгънә юк иде. Мәрьямбану трубканы куйды. Бу хатынның үзенә больница кирәк тә бит, ә ул әнә чәчәк кебек кызын шунда илтеп тыкты. Ләйләне диненнән аерам, башкалар кебек ясыйм дип, чын күңелдән инанып, үз ихтыяры белән баласын дин дошманнары кулына илтеп тапшырды. Анда алган коточкыч көчле дарулар тәэсирендә, хәзер инде Ләйлә кеше дә танымый башлаган. Мәрьямбануны хәзер больницага кертмиләр, Ләйләнең өенә якын җибәрмиләр, югыйсә кода-кодагый буласы кешеләр иде бит.

Ләйлә белән нәрсә булганын Мәрьямбану үзе дә аңламый калды. Өйдә ата-анасының дин тотмавын, Ләйләгә дә гел бәйләнеп торуларын белә иде ул. Әмма Әхмәт монда вакытта, инде Ләйлә белән өйләнешү турында сөйләшеп йөргәнлектән, әти-әнисе Ләйләгә киселгән икмәк, кеше кешесе кебегрәк карый башлаганнар иде. Кызларының дин юлына кереп китүенә килешкәннәр кебек иде. Әхмәт китү белән, барысы да үзгәрде. Иң башта Ләйләне мәдрәсәгә йөрүдән тыйдылар. Аннан Мәрьямбануны өйләренә кертми башладылар. Мәрьямбану үзе аларга йөгереп керде — ачмадылар, телефоннан җавап бирмәделәр. Ә беркөнне Мәрьямбану мәдрәсәдә укучы кызлардан Ләйләнең психбольницада ятуын белде. Бу хәбәрне ишетү белән ул больницага йөгерде. Караватында бөгәрләнеп, баштанаяк капланып яткан Ләйләне ул танымады. Ләйлә дә аңа куркып, гаҗәпләнеп карап торды.

— Ләйлә, акыллым, нәрсә булды сиңа, балакаем?! — Мәрьямбану Ләйләне кочаклап елап җибәрде.

Ләйлә дәшмәде. Бу хәлне күреп, Мәрьямбануның башына «әллә, чыннан да, авыруы хакмы икән?» дигән куркыныч уй да килде. Ул бу ямьсез уйны тизрәк үзеннән куарга ашыкты.

— Әхмәттән хәбәр юкмы соң, сеңелем? — дип сорады ул сак кына.

Хәбәр югын үзе дә белә иде, әмма Ләйләне бу битараф халәтеннән чыгару өчен Мәрьямбану соңгы җепкә тотынды — Әхмәтнең исемен әйтеп карады.

Ләйлә, гаҗиз булып, тагы озак кына Мәрьямбануга карап торды. Аннан, йөзен Мәрьямбануның җилкәсенә яшереп, елап җибәрде.

— Нигә мине ташладың син, Мәрьямбану апа?

Ләйләнең бу сүзләре, бу соравы бер дә акылсыз кеше сүзенә охшамаган иде. Әмма шулай дип соравы барыбер сәер иде.

— Нигә алай дип әйтәсең, акыллым? Мин бит синең өеңә дә кердем — ачмадылар, шалтыратып карадым — алмадылар... Мәдрәсәгә йөрми башладың, безгә кермисең... Мин нәрсә уйларга да белмәдем инде.

— Әни сезнең белән араны өзәргә кушты. Әхмәтнең шунда үлеп калуын тели, алардан шулай гына котыла алабыз, ди, сине бозганнар, дип бара, сездән шикләнә. Шуңа күрә мәдрәсәгә дә йөртми, сезгә дә кертми.

Мәрьямбану Ләйләнең әнисе дингә каршы икәнен белә иде. Гомер буе базарда сату иткән бу хатын дин тотучыларга эшлексез ялкаулар, дип кенә бәя бирә иде. Имеш, аның кебек көне-төне эшләсәң, дөнья кусаң, бит сыпырып утырырга вакыт калмый ул...

Кызының дингә килүенә, мәдрәсәгә йөри башлавына ул башта бер кызык итеп кенә карады, әйдә, кылансыннар, ичмасам, башкалар кебек аракы эчеп, зина кылып йөрмәс дип уйлады. Аннан кызы яулык бәйләп, озын күлмәкләр кигәч, курка ук калды. Чөнки Ләйлә алар ашаганны ашамады, телевизорга якын килмәде, алар белән бергә татарча концерт-театрларга да йөрмәс булды. Ана кеше төннәр буе намаз укыган кызына шикләнеп карый башлады. Кыз да әнисенә кызганып һәм әрнеп карый иде. Чөнки аларның бөтен тормышлары аракыдан тора иде. Әнисе базарда аракы сатып кына калмый, өйдә дә гел аракы тота, төннәр буе алар ишеге ннән кеше өзелми иде. Әтисе белән әнисенең еш кына кухняда чәкештереп эчеп утыруларын күреп, кыз бала кайгыга кала иде. Ләйлә әнисенә әкренләп бу хакта әйткәли дә башлады, әмма әнисе: «Сезне монда кем туйдырыр, аракы сатмасаң?» — дип кенә акырды. Ана белән бала арасында берберләрен аңламау, бер-берләреннән ризасызлык артканнан-арта барды. Әхмәт монда вакытта ана кеше тешен кысып түзде — өйләнешерләр дә, аның янына чыгып китәр, үз көннәрен үзләре күрерләр дип уйлады. Әмма менә алай килеп чыкмады шул. Әхмәт юкка чыкты, Ләйлә, шушы озын күлмәк-яулыкларына чорналып, берүзе утырды да калды. Шунда гына ана кеше үзенең никадәр авыр хәлгә төшкәнлеген аңлады. Ул Ләйләнең карт кыз булып утырып калуыннан курыкты, ә бу кыяфәтендә Ләйлә янына егетләр якын да килмиләр иде. Ләйлә үзе дә монашка кебек бүлмәсенә кереп бикләнгән — ни егетләр, ни өс-баш, ни күңел ачулар... Ана кеше уйлавынча, кызы күз алдында харап булып, юкка чыгып бара иде. Һәм ана кеше Ләйләне үзгәртергә, дәваларга

алынды... Бу «төзәтү»нең нәтиҗәсе психбольница белән тәмамланды...

Башта ул Ләйләне карчыклар кебек чорналып урамга чыгудан тыеп карый. Ләйлә, әлбәттә, тыңламый. Аннан ана кеше аны мәдрәсәгә йөрүдән тыя, Ләйлә янына беркемне кертми, үзен дә бер җиргә чыгармый, бикләп үк куя. Моңа җавап итеп, Ләйлә ашаудан баш тарта. Кызын яклап, исерек ата да кушылып карый, әмма гомер буе базарда сату иткән хатын ирен дә тиз акылга утырта. Үзен башкача яклый алмагач, Ләйлә анасы белән бөтенләй сөйләшми башлый. Ашамыйча коры сөяккә калган, айлар буе беркем белән дә аралашмаган, төннәр буе шәүлә кебек намаз укып утырган кызы ана кешегә шикле булып тоела. Кызын бозганнар дигән уй аның башына чыкмаслык булып кереп утыра. Өй сихерчеләр, күрәзәчеләр, өшкерүчеләр һәм төкерүчеләр белән тула. Әмма Ләйләнең хәле яхшырмый, ул, беркем белән сөйләшмичә, бикләнеп яшәвен дәвам итә. Ә беркөнне, карадан киенгән карчыклар шәмнәр тотып төкеренә-төкеренә янәшәсендә әйләнеп йөри башлагач, ул түзми:

— Сез барыгыз да тәмугта яначаксыз! — дип кычкыра. — Сине дә җәһәннәм көтә, әни. Болай яшәвеңне ташламасаң, сине җәһәннәм көтә... Сез барыгыз да яначаксыз, яначаксыз!..

Карчыклар, котлары чыгып, «җен иярләшкән, җен оялаган» дип пышылдашып, өйдән чыгып качалар. Сихерчеләр дә җиңә, дәвалый алмаган кызына ана кеше психбольницадан бригада чакырта. Яулыкка чорналган, шыр сөяккә калган кызны психбольницадан килүчеләр карап та тормыйлар, «паспорты йөзендә» дип, «ашыгыч ярдәм» машинасына утыртып, алып чыгып та китәләр. Шулай итеп, Ләйлә юләрләр йортына килеп эләгә...

Ләйлә, елый-елый, Мәрьямбануга менә шушыларны сөйләде.

Больницада Ләйләне шунда ук система астына салалар, тәненә, кан юлларына, башына көчле дарулар җибәрәләр, укол белән ашата, укол белән йоклата башлыйлар. Ләйләнең күз алмалары зурайган, йөзе саргаеп сузылган, бармаклары туктаусыз дерелдәп тора иде.

— Мәрьямбану апа, мине монда калдырма, — диде ул, аның кулларына чытырдап ябышып. — Миңа монда намаз да укытмыйлар, мәдрәсә кызларын да кертмиләр. Бик куркыныч уколлар ясыйлар... Мине монда бетерәләр, Мәрьямбану апа...

Мәрьямбану үзе дә Ләйләне моннан алып чыгып китәргә ниятләгән иде инде. Ул аны үзләренә алып чыгачак. Ничек башта ук бу уй аның башына килмәгән соң? Кеше баласы бит, анасы барыбер рөхсәт бирмәгән булыр иде. Эшләр бо-

лай куркынычка киткәч, анасы белән дә исәпләшеп тормаска туры килер, югыйсә бала күз алдында бетеп бара...

Ул арада, кемдер хәбәр итеп, ахры, бүлмәгә җилфердәп карт кына бер кеше килеп керде. Мәрьямбану аны элеккеге елларда шәһәр активы җыелышларында күргәне бар иде. Бу — больницаның баш табибы Штейнберг дигән яһүди. Ул да Мәрьямбануны төсмерләп алды, ахры, коры гына сорап куйды:

— Сезне монда кем кертте?

Мәрьямбану да югалып калмады, бу яһүдине закон белән куркытып кына җиңеп буласын ул яхшы белә иде:

— Бу кыз — минем укучым, күрше кызы, ул гына да түгел, Ләйлә минем булачак киленем, — дип башлады ул үзенең хокукларын күбрәк күрсәтергә тырышып. — Ул авыру түгел, бирегә ялгыш эләккән. Минем аны алып чыгып китәргә тулы хакым бар.

Карт еврей йомшара төште, әмма чигенергә ашыкмады. Чигенергә уйламады да. Ул эченнән генә ишек төбендә утыручыларны сүкте, чөнки монда мөселманнарны, бигрәк тә яулык бәйләгән хатын-кызларны кертмәскә катгый рәвештә әйтелгән иде бит! Ул аларның монда килеп, хокук даулап йөриселәрен белде, бу кыз баланы алып чыгып китәргә тырышасыларын да чамалады. Әмма Штейнберг кулына килеп эләккән кешегә үз акылында моннан чыгу юк иде инде. Штейнберг, хокук-хак темасын әйләнеп үтеп, башка сүзгә күчте:

— Күрәсезме, сез авыруны нинди хәлгә китергәнсез? — диде ул, Ләйләнең калтырап торган кулларыннан алып. Аннан гипнозлы-лазер күзләре белән аның акылында, күңелендә актарына башлады, үзе һаман Ләйләне юаткан, тынычландырган кебек итенде. — Ә син тынычлан, Ләйлүш, тынычлан, кара, нишләткәннәр үзеңне? Кара, бөтенләй калтырый ук башлагансың, кара, йөрәгең ничек тибә, кара, ничек агарынгансың...

Ләйлә, чыннан да, Штейнбергның күзенә кереп бетәрлек булып, бөтен гәүдәсе белән дер-дер калтыранып, буыла-буыла елый ук башлады. Мәрьямбану, коты чыгып, сикереп торды. Әле яңа гына ягымлы, йомшак сөйләшеп утырган Ләйләне танырлык түгел иде. Ул арада ике шәфкать туташы йөгереп килеп, Ләйләнең кулларын артка каерып, аркасына, беләкләренә берничә укол кададылар. Ләйлә күз алдында шәлперәеп, шиңеп төште... Мәрьямбану аңа эндәшеп-эндәшеп карады, әмма Ләйлә инде аны да, янындагы табибларны да күрми, танымый иде... Ул тагы уянмас йокысына китте...

Икенче көнне Мәрьямбануны больницага якын да җибәрмәделәр. Башындагы яулыгын башлыкка да алмаштырып барып карады — әмма аны Ләйлә янына кертмәделәр.

Штейнберг Ләйлә янына әнисеннән башка беркемне дә кертмәскә әмер биргән иде.

Бу хәлләр моннан берничә көн элек булды. Мәрьямбану, суд аша булса да берәр чара күрермен дип йөргәндә, менә бүген улының хәбәре китереп бәрде. Әйтерсең лә ниндидер кара көч бу мөселман балаларын җир йөзеннән кырып, юк итеп чыгарга җыена иде. Ялгыз ана нишләргә дә белмәде. Бер якта — улының кайгылы хәбәре, икенче якта — Ләйлә үлем тырнагында... Стена аша гына ире чит хатын белән яшәп ята... Һәм шушыларның барысына да түзәрлек, барысын да күтәрә һәм җиңеп чыга алырлык көчле рух, иман кирәк, сабырлыклар кирәк... Мәрьямбану аңлый — бу газаплар, бу авырлыклар — Аллаһы Тәгаләнең сынавы...

Барысы да кисәк кенә үзгәрде дә куйды: ире бар иде — ире ташлап китте, улы бар иде — улы җиһадка китте. Дәрәҗәле эше, зур исеме бар иде — берсе дә калмады... Барысы да дингә килгәч башланды... Бер татар хатынының чын күңелдән дингә килүе, исламча яши башлавы иренә дә, иленә дә кирәк түгел иде. Тормышының кыл уртасында Мәрьямбану юллар чатында калды — гомерне элеккечә динсезлектә, дин тотмыйча яшәп бетерергәме, әллә, соң булса да, Аллаһ юлыннан китәргәме? Мәрьямбану соңгысын сайлады. Һәм Мәрьямбану барысын да югалтты — үзен чорнап алган дөнья аны бу кыяфәтендә танымады, кабул итмәде, кирәген тапмады. Мәрьямбану үзе дә азган-тузган бу динсезләр дөньясы белән арасын өзде, ул куйган таләп һәм кагыйдәләрне кабул итмәде, танымады. Һәм беркөнне япа-ялгыз калды. Ул дөньяны үзгәртә алмады, шулай ук дөньяга да үзен үзгәртергә ирек бирмәде...

Барысы да дингә килгәч башланды... Аллаһы Тәгалә шулай иң кадерлеләреннән аерып сыный идеме Мәрьямбануны, әллә аны тагы да дәһшәтлерәк, куркынычрак сынауларга әзерли идеме — Мәрьямбану анысын белми иде. Бу сынауларның, бу авырлыкларның барысы да Аллаһы Тәгаләдән икәнен генә белә иде ул... Һәм Раббысыннан, нинди генә авырлыклар күрсә дә, шушы хак юлыннан аермавын, иман ныклыгы бирүен сорый иде...

Ә бәндәсе өчен нәрсәнең хәерле булуын бары тик Аллаһы Тәгалә үзе генә белә...

Мәрьямбануның борчулы уйларын сизенгәндәй, стена артында Тимербулатларның эте елый башлады. Гел шулай — Мәрьямбанулар ягында бераз гына борчу-хәсрәт булдымы, эт стенаны тырный-тырный шыңшый башлый. Эт булып эт сизенә бу йортта нидер булып ятканын, Әхмәтнең юклыгын, аңа бәла килгәнен, ә Тимербулат, Әхмәтнең әтисе, берни сизенми, борчылмый микәнни? Телевизордан ул да ишеткәндер бит инде. Бала кайгысы аның йөрәгенә килеп бәрелмә-

деме икәнни, күрше марҗа сихереннән бала кайгысы да аралый алмасмы инде ул кешене? Мәрьямбануның ирен, Әхмәтнең атасын?! Нигә шушындый зур кайгылар килгәндә алар бергә түгел соң, ничекләр күтәрсен Мәрьямбану бу хәтле хәсрәтне — бала хәсрәтен?..

Көн җилләп-давыллап торды да кисәк кенә караңгылатып җибәрде. Әле кояш баемаса да, бөтен дөньяны кара болытлар каплап киткән һәм бу шәһәргә, бу йортка мәңгегә төн килгән кебек иде. Мәрьямбану хәсрәтле уйларыннан айнып киткән кебек булды. Йа Хода, бала кайгысы намазын да оныттыра язган, сабырлыкларын да сындырып, уйларын чуалтып-таратып ташлаган. Мәрьямбану ашыгып икенде намазына басты. Икенде намазы — фәрештәләрнең аерата яраткан, бәндә белән бергә укый торган намазлары. Бәндәгә иң якын вакытлары... Мәрьямбану Аллаһы Тәгаләдән бер генә нәрсә сорады — шушы хәл-хәбәрләргә дә түзә, шуны күтәрә алырлык иман ныклыгы һәм сабырлык. Баласын ул Аллаһы Тәгаләгә тапшырды, хәерлесен дә Ул кылыр. «Раббым, балам белән Җәннәтләрдә күрешү бәхетләре бир», — дип сорады Мәрьямбану намазлыгына тезләнеп. Тәкъдирдән качып булмаганын ул бик яхшы белә иде, ә Тәкъдир китабының серләре бары тик Аллаһы Тәгаләгә генә билгеле иде...

Намазлыгы өстендә күпме шулай утыргандыр — Мәрьямбану хәтерләми. Ниндидер сәер кыштырдауга сискәнеп, ул башын күтәрде. Тавыш килгән якка борылып карагач, ул куркуыннан кычкырып җибәрә язды. Җәйдән кереп калган чикерткәләр, бер рәткә тезелеп, сәер сикеренә-сикеренә, өйне ташлап чыгып баралар иде... Менә алар Мәрьямбану турына килеп җиттеләр, менә алар, Мәрьямбануга игътибар да итмичә, сикерә-сикерә, намазлык өстеннән үтеп тә киттеләр, менә алар ишеккә җиттеләр, үзләре генә белгән тишекләр, ярыклар аша, ничек кергәннәр, шулай юкка да чыктылар... Мәрьямбану утырган урынында катып карап калды. Бу — бәла буласына иде... Йортны җан ияләре ташлап кача, бу — бәлагә, зур афәтләргә иде...

Ишектә яңгыраган кыңгырау тавышы аңа шушы афәтләрнең башы булып тоелды. Мондый кайгылы көндә кем кагылыр аның ишегенә, аның бусагасын күптән урап үтәләр бит инде, Чечняда шушы хәлләр башланганнан бирле. Үзәген телгәләп, тагы улы күз алдына килде, намаз вакытында бераз онытылып торган борчулы уйлары тагы башына ябырылды. Бүген көндез Хәйдәрнең телевизордан әйткәннәре миенә сугып, өзлексез сулкылдап тора башлады. Тукта, ишектә, бәлки, Хәйдәрдер? Мәрьямбануга үзе дөресен әйтергә килгәндер, бу телевизордан ишеткәннәр барысы да ялгандыр, исәндер аның улы, исәндер!

Мәрьямбану кабаланып ишеккә ташланды. Сорамыйча да ачып җибәрде.

Ишек төбендә Тимербулат басып тора иде...

Алар ишек төбендә күзгә-күз карашып озак басып тордылар.

— Белеп килдеңме? — диде Мәрьямбану.

— Нәрсәне? — Тимербулат шомланып Мәрьямбануга карады.

«Димәк, белми. Бәлки, белмәве хәерлегәдер...»

Тимербулат бүлмәгә үтте, кайчандыр гомеренең иң кадерле мизгелләре узган бу урынга ул хәзер чит кеше кебек, рөхсәт сорап кына керә ала иде. Бүген исә Тимербулат көне буе үзен кая куярга белмәде, иртәдән бирле җаны уйнады, кичкә таба күңелен бөтенләй шом басты, аяклары бу якка тартты. Әйтерсең лә Мәрьямбануның нурдан, аклыктан гына торган бу бүлмәсе Тимербулатны тынычландыра, юата ала иде... Тимербулат үзе барып зур утны яндырды, пәрдәләрне тартып куйды. Бүлмә эче тагы да яктырып, нурланып киткән кебек булды. Тимербулат та бераз тынычланды. Әмма Мәрьямбану гына бүген аерата хәсрәтле, аерата борчулы күренде Тимербулатка. Элеккеге еллардагы кебек, кулларына күтәреп аласы, үзләре генә белгән иркә сүзләр белән юатасы, тынычландырасы килеп китте. Әмма Мәрьямбану Тимербулаттан йөз ел барсаң да барып җитә алмаслык ераклыкта иде шул... Алар күптән инде икесе ике дөньяда яшиләр иде...

— Йә, нәрсәгә ирештең инде шушы юлдан китеп?

Тимербулат бу сорауны Мәрьямбануга инде мең дә беренче мәртәбә бирә иде. Мәрьямбануга нинди генә авырлыклар, бәхетсезлекләр килсә дә, җир астыннан чыккандай каршына килеп баса да, шушы бер сорауны бирә:

— Йә, нәрсәгә ирештең инде... шушы юлдан китеп?

Үзе шулай ди, үзе Мәрьямбануның «ялгыштым шул, Тимербулат, элеккечә генә яшисе калган икән, берни үзгәртмичә» дип әйткәнен көтә. Мәрьямбану әйтми, элеккеге кебек яшәргә дә җыенмый. Һаман шул юлында... Шул юл дигәне — дин юлында дигән сүз.

Башта ук каршылык шуннан китте. Тимербулат мәсьәләне «йә — дин, йә — мин!» дип куйды. Мәрьямбануның кырык яше дә тулмас борын карт әбиләр кебек яулык бөркәнүләрен дә кабул итмәде ул, парлашып мәҗлесләргә бармавын да, концертларга йөрми башлавын да аңламады, төн урталарында, Тимербулатның кайнар кочагыннан чыгып китеп намаз укып йөрүләрен дә өнәп бетермәде...

Юк, Тимербулат дингә каршы кеше түгел иде. Ләкин ул дин аның тормыш тәртипләрен, ияләнгән гадәтләрен бозарга,

аны бу дөнья рәхәтлекләреннән аерырга тиеш түгел иде. Тимербулат үзе дә заманында мәчетләр салдырып, корбаннар чалдырып, дин, милләт дип мәйданнарда кычкырып йөргән кеше. Хәер, ул вакытта алар өчесе бергә иде, бер сүздә, бер юлда, бер уйда иделәр. Гаиләләре белән милли хәрәкәт уздырган бөтен митингларда йөрделәр, бер җыелышны, бер татарча концерт-театрны калдырмадылар. Ун яшенә кадәр бары тик урыс балалар бакчасына, урыс мәктәпләренә генә йөргән, өйдә дә ата-анасы белән бары тик урыс телендә генә сөйләшкән Әхмәт мәйданнан «Азатлык» сүзен отып кайтты. Һәм шул көннән соң инде ул бу сүзне онытмады. Ул арада шәһәрдә күпләп татар мәктәпләре, татар гимназияләре ачыла башлады, Әхмәтне, ике дә уйлап тормыйча, татар гимназиясенә илтеп бирделәр. Әхмәт белән бергә, өйгә Тукай шигырьләре, татар җырлары, малайның тормышына үзе кебек үк яңа рухлы татар балалары килеп керде. Аларның барысын да «бәйсезлек балалары» дип йөртәләр иде. Чөнки бу татар балалары ата-аналары белән мәйданнарда «Азатлык» кычкырып йөргән, кышкы салкыннарда, җәйге челләләрдә урамнарда митинг-пикетларда басып торган, сайлау, референдум вакытларында листовкалар таратып йөргән балалар иде. Бу еллар, мөгаен, Тимербулатның гомерендә иң кадерле, иң кыйммәтле, иң мәгънәле еллар булгандыр. Аннан барысы да үзгәрде, бетте. Бәйсезлек тә калмады, милли хәрәкәт тә, гаиләсе дә... Алар белән бергә тормышының мәгънәсе, максаты да...

Дәшмичә шактый озак утырдылар. Тимербулат үзе дә аңлый — эш Мәрьямбануның дингә килүендә генә түгел иде. Ул сәбәп кенә. Эш башкада — милләт дип, бәйсезлек дип ыргылып чапкан бер чорында Тимербулат милләтенең дә, бәйсезлекнең дә юк икәнен тоя башлады. Болар барысы да уен гына булган икән... Кемгәдер — хакимияткә килер өчен, кемгәдер — хакимияттә калу өчен... Һәм, көннәрдән бер көнне, аны, шәһәрнең танылган бер кешесен, эшмәкәрен, милләтчесен, чакыртып алдылар да әйттеләр: «Уен бетте, егетләр», — диделәр. Тимербулат телсез-өнсез калды — нинди уен, кем өчен, нәрсә хакына уен? Ул, ир уртасы кеше, менә инде ничә еллар буе хатынын, баласын җитәкләп, мәйданнарда йөргән, берәмтекләп мәктәп-мәчетләр ачтырган, чын күңеленнән Татарстан бәйсез булсын, бәхетле булсын дип йөргән кеше — ул да уен уйнаган булып чыгамыни инде? Кем уены, кем файдасына уен? Монысын да ирләрчә аңлаттылар Тимербулатка — милләтчеләр ярдәме белән Татарстан Мәскәүдән ала алырдаен алган икән, хәзер исә урамнарда кычкырып йөрер вакыт үткән, киресенчә, җитәкчеләрне якларга, аларны Мәскәү кысуыннан сакларга кирәк икән... «Кирәк чакта без

сезне чакыртып алырбыз, тагы урамнарга чыгарсыз, Мәскәүне куркытып алырсыз», — диделәр... Ул арада күпләп завод-фабрикалар ябыла башлады, инде менә була, менә бәйсезлек алабыз да, рәхәт яши башлыйбыз дигән халыкны эшсез-акчасыз урамнарга куып чыгардылар. Милләт фәкыйрьлеккә төште, ата-аналары — эшсез, балалары, акча булмау сәбәпле, белемсез кала башлады. Бу хәерче, надан татарлар беркемгә дә кирәк түгел иде. Моны милләт үзе дә сизде, тормыштан күңелләре кайткан, инде беркемгә, бернәрсәгә дә ышанмаган, өмет итмәгән ата-аналар — аракыга, балалары наркотикларга барып ябыштылар...

Менә шул вакытта Тимербулат та ике ут арасында калды. Бер яктан: «Кайда эш, кайда хезмәт хакы, кайда кычкырып йөргән бәйсезлегегез, ник безне иске тормышыбыздан аердыгыз?!» — дип, халык ябышса, икенче яктан, Тимербулат кебек милләтчеләр инде җитәкчелек өчен дә кирәк түгел иде. Аларны зур сәясәткә дә, зур бизнеска да якын китермәскә тырыштылар, дөнья белән идарә итәргә яңа байлар, яңа татарлар килгән иде. Алар бу елларда эшләп түгел, бары тик халыкныкын һәм дәүләтнекен талап кына аякка басып калдылар. Моны бөтен кеше белә иде. Әмма халык бәгыренә төшкән шушы татарларга сүз әйтә башласаң, алар бердәмлек турында чүбек чәйни башлыйлар иде, имеш, нигә инде Мәскәүләр алдында, башка милләтләр арасында татар татарга сүз әйтә, татар татарны сата? Менә сиңа мә! Татар татарны таларга, рәнҗетергә ярый икән, ә шул турыда сүз әйтә башласаң — син татарны, булмаган бәйсезлекне сатучы...

Бу хәлләрне аңлаучы милләтчеләргә бик авыр иде. Яңа татар байлары хакимият һәм байлыкны кулга төшерү белән генә чикләнеп калмадылар. Әкренләп аларга барлы-юклы татар мәктәпләре, татарлык та комачау итә башлады. Бу татарча мәктәпләр, мәчет-мәдрәсәләр дә алар өчен уен гына булып чыкты. Шул чагында улының әйткән сүзләрен һаман да хәтерли әле Тимербулат:

— Әти, бәйсезлек беттемени инде?

— Нигә алай дисең, улым?

— Гимназиядә шулай диделәр. «Азатлык» дип больше кычкырып йөрмәгез, милли хәрәкәттә анда бандитлар гына калды, диделәр...

Икенче көнне үк кызып-ярсып, улы укыган гимназиягә китте Тимербулат. «Милли хәрәкәттә бандитлар гына калды» дигән укытучыны да эзләп тапты. Карт тарихчы акланып маташмады, киресенчә, Тимербулат авыз ачуга, үзе һөҗүмгә күчте:

— Әйттем шул, — диде ул Тимербулатның күзләренә туры карап. — Хәзер дә әйтәм — нигә монда килеп, татар

мәктәпләренең астын өскә китереп, тикшереп йөргән булалар? Без монда болай да татарча укытабыз. Алай бик батырлар икән, әнә урыс мәктәпләрен барып актарсыннар, анда татар балаларын чукындырып яталар. Бик батырлар икән, әнә җитәкчеләрдән барып сорау алсыннар — нигә үзләре татарча сөйләшмиләр алар? Безне тикшерүче болай да күп. Без ябылып беткәч, менә кемне тикшерерләр?

— Син, агай, давай бөтенесен бергә өймә әле, яме! Әле беркем дә татар гимназияләрен ябарга җыенмый, үзара талашып-ызгышып кына таралып бетмәсәгез.

Карт укытучының бик тиз хәтере калды.

— Мин сине акыллырак кеше дип уйлаган идем, энем, — диде ул кызарынып-бүртенеп. — Ярый, милли хәрәкәт әбиләре монда килеп кычкырсыннар да инде, алар төптән күрми. Соң син ир кеше, аңларга тиеш бит — киләчәге юк бу татар мәктәпләренең! Нигә дисеңме? Йә, байрак болгап йөреп, хет бер татар университеты ачтыра алдыгызмы? Кая барсыннар бу татар мәктәпләрен бетергән балалар? Аларның башларында русчасы-татарчасы барысы буталган бит — кайсы бишенчедән, кайсы алтынчыдан татарча укый башладылар. Нәтиҗәдә ни физика-математика кебек фәннәрне урысча аңлата алмыйлар, ни чатнатып сөйләрлек татарчалары юк.

— Анысы сезнең гаеп инде, агай, укытырга, өйрәтергә кирәк иде, сезнең кулда бит.

— Син, энем, алай бик акыллы булгач, башкасын да сора. Мин ничә ай хезмәт хакы алмадым икән? Сорамасаң да әйтәм — биш ай! Без хатын белән икебез дә укытучы, ярты елга якын бушка эшлибез. Безнең өйлә ризыгы өчен түләргә акчабыз юк, өйдән бәрәңге пешереп алып килеп, укучылардан кача-поса шуны ашыйбыз. Син тел, дисең! Безнең күбебездә хәзер баш кайгысы, тамак кайгысы. Сез бәйсезлек, дип йөрмәсәгез, без бу көннәргә калмый идек!

— Туктале, агай, монда бәйсезлекнең ни катнашы бар соң?

— Бар! Без элек болай яшәми идек — акчасын да вакытында ала идек, диңгезенә ял итәргә дә бара идек, чират буенча квартирасын да ала идек. Халыкның бөтен байлыгын, бөтен хокукларын сез бер төркем карак кулына алып бирдегез! Имеш, аларга бәйсезлек кирәк, имеш, хәзер халык бай яшәячәк... Саттыгыз! Сатылдыгыз! Булган малдан, дәүләттән һәркем үзенә калҗа-калҗа йолкып калырга тырыштыгыз! Безгә нишләргә хәзер? Балалар җәл, без аларны моңа кадәр гел бәйсезлек дип, милләт дип тәрбияләдек. Хәзер нәрсә дип әйтик аларга? Кем аркасында шулай булды дип әйтик?

Тимербулатны бу авыр сөйләшүдән кыңгырау гына коткарды. Аның карт тарихчыга әйтер сүзе, төпле җавабы юк

иде. Чөнки Тимербулат үзе дә менә инде күпме гомер нәкъ шушы сораулар, шушы борчулар арасында бәргәләнә иде. Ул, башын иеп, коридорга чыкты. Тимербулат шуңа да игътибар итеп өлгерде — балаларның күбесе урысча сөйләшә иде. «Инде татар мәктәпләрендә дә шушы хәл булгач!» дип рәнҗеп уйлады Тимербулат. Нәрсә өчен ачтырдык соң алайса без бу мәктәпләрне, татар укытучыларына эш булсын өченме?!

Ул инде, ник килгәненә үкенеп, кайту ягына борылган иде. Шулчак колагына саф татарча, матур итеп сөйләшкән тавышлар ишетелде. Тимербулат терелеп киткән кебек булды, гаҗәпләнеп, шул якка борылып карады. Тәрәзә янында улы Әхмәт белән күрше балалары Ләйлә һәм Хәйдәр басып торалар иде. Дөньяларын онытып татарча сөйләшүчеләр дә алар икән. Әмма Тимербулатны гаҗәпләндергәне башка иде. Ул улының күрше кызы Ләйләне ошатып йөрүен сизенә иде, кыз да Әхмәткә битараф түгел, ахрысы, бөтен җиргә дә алар икесе тагылган кебек йөриләр. Әмма өченче дус Хәйдәр дә кызны бер генә минутка да ялгызын калдырмый, Ләйләнең бер ягында Әхмәт булса, икенче ягында — Хәйдәр... Менә монда да нәкъ шул күренеш: Әхмәт — бер яктан, Хәйдәр икенче яктан Ләйлә тирәсендә күгәрчен кебек гөрлиләр, ә кыз исә икесенә дә карап елмая, икесен дә якын иткәнлеге күренеп тора.

«Әмма кайчан да булса берсенә тукталырга туры киләчәк, сеңелкәй, кайчан да булса берегезгә юлдан китәргә туры киләчәк, егеткәйләр» дип уйлады Тимербулат, һәм, балаларга күренеп оялтмас өчен, шыпырт кына мәктәптән чыгып китте.

Яшьләрне күргәч, аның күңеле бераз күтәрелеп киткәндәй булды. Нәрсә генә булса да — бәйсезлек бармы ул, юкмы, халык бәхетлеме, бәхетсезме — тормыш дәвам итә иде. Кемнәрдер барыбер гашыйк була, кемнәрдер гаилә кора, кемнәрдер оныклы була, бабай була... Тимербулат елмаеп куйды. Эшләр болайга барса, әле туйлар да озак көттермәс, күрше кызының барыбер аның улын сайлыйсын белә Тимербулат, һәм шушы кечкенә генә шәхси шатлык, кечкенә генә өмет тә аны тагы дәртләндереп, яшәртеп җибәрде. Ул барысын да онытып, куанычын Мәрьямбану белән уртаклашырга өенә ашыкты...

Ул һәрвакыт өенә шулай ашыгып, атлыгып кайтып керә иде... Дөньядагы бөтен кайгыларын һәм шатлыкларын, бөтен борчуларын, өметләрен иң беренче булып Мәрьямбануы белән уртаклаша иде... Бөтен шәһәрендә, бөтен милләтендә, бөтен дөньясында алар кебек бәхетле, алар кебек бер-берләрен аңлый һәм яратыша торган кешеләр юк иде бит! Юк иде...

Тимербулат соравын тагы бер тапкыр кабатлады:

— Нәрсәгә ирештең дип сорыйм бит... шушы юлдан ки-

теп? Менә кайда ул бала хәзер? Син бит аны чит илдә укый дип алдыйсың, чит илдә укыган баланың ата-анасын көн саен КГБдан тикшереп тормыйлар… Мин аның кайда икәнен син әйтмәсәң дә беләм инде… Шунда ул, шунда… Римманың кәртләре да шулай күрсәтә, ә ул белмичә әйтми инде…

Римма — Тимербулатның хәзерге хатыны, бөтен шәһәргә танылган күрәзәче. Мәрьямбануның йөрәге тагы чәнчеп-чәнчеп куйды — монда да ул хатын. Кара кайгы көнендә дә арада шул кара хатын… Тимербулат Мәрьямбану барган юлдан барырга теләмәде, ә бу хатын үз артыннан алып китте. Һаман ычкындырганы юк. Хәер, зинага кызыккан, хәләлен үз теләге белән харамга алыштырган Тимербулат, кайчандыр аның ире, баласының атасы булган мондый Тимербулат кирәк идеме икән Мәрьямбануга? Әхлаксыз, динсез, бозык Тимербулат кирәк идеме — хәтта баласының атасы булса да?

— Безнең аерылуда минем бу юлдан китүемнең гаебе юк, Тимербулат, — диде Мәрьямбану. — Син моны үзең дә яхшы беләсең. Син башка юлдан киттең, син гаиләңне ташладың, син харамга үрелдең…

— Әмма мин синең белән араны өзмәдем бит! Син аңларга теләмәдең.

— Син инде башка кеше идең… Һәм төзәлергә дә теләмәдең…

Мәрьямбану өчен бу сөйләшү бик авыр иде. Бигрәк тә бүген, улы турында шундый кайгылы хәбәр ишеткән көнне… Аның Тимербулатка барысын да сөйләп бирәсе килде, элеккеге еллардагы кебек, башын җилкәләренә салып, күңелендәге барлык уй-борчулары белән бүлешәсе килде. Элек һәр кичне ул аңа үзе турында, күңеле турында сөйли иде, фикерен, киңәшен сорый иде. Хәтта Тимербулат өйдә юк вакытта да, күңеленнән гел аның белән сөйләшеп, киңәшеп йөри иде. Ә хәзер — ике арада таш стена… Таш стена артында — Тимербулатның икенче тормышы, чын тормышы, бүгенгесе… Мәрьямбану — үткәннәрдә һәм хатирәләрдә генә… Ике арада тәкъдирнең пәрдәсе тора…

— Бар, чык инде, Тимербулат, — диде Мәрьямбану, аңа күтәрелеп карамыйча гына. — Минем дә намаз вакытым җитте. Хатының да дөрес аңламас…

— Менә шул намазыңны кочаклап калдың инде. Янында ни ирең, ни улың. — Тимербулат тимер кебек авыр сүзләрен, салкын сүзләрен Мәрьямбану өстенә ташлап, китәргә ашыкты.

— Мин сине кумадым, Тимербулат, үзең киттең… Минем гаебем булса, кичер, бәхиллегеңне бир.

Тимербулат сүзсез, тынсыз-өнсез калды. Мәрьямбануның гап-гади итеп әйткән бу сүзләрендә бөтен дөреслек, ачы хакыйкать, төзәлмәслек яра — фаҗига иде. Әйе, Тимербулат

үзе китте бу йорттан, Мәрьямбану аны кумады, ул ир куа торган хатын түгел. Әмма аларның аралары ир белән хатын булып яшәп калырлык та түгел иде инде. Алар икесе ике дөньяда яши башлаганнар иде... Мәрьям белән Әхмәт башаяклары белән дингә кереп киттеләр, тормышны шуңа көйләделәр, Тимербулат өчен исә ул тормыш чит-ят, тар һәм чикләнгән кебек тоелды. Ә янәшәдә генә икенче тормыш — шаушулы, ләззәтле, гөнаһлы тормыш көтеп тора иде аны. Тимербулат шунысын сайлады. Һәм бу йорттан да үзе чыгып китте. Гаеп тә Тимербулатның үзендә. Ул чагында нигә аннан кичерү, бәхиллек сорый соң Мәрьямбану? Нигә ул бүген шулай сәер, моңлы, әйтерсең дөнья белән саубуллаша, дөньядан китә? Тимербулатның аяк астында җир селкенеп куйган кебек булды. Барысына да түзәргә риза, гомер буе көтәргә дә риза, әмма стена аша булса да Мәрьямбануның йөрәге генә типсен, ул гына яшәсен... Тимербулат үзе аннан кичерү, бәхиллек сорарга әзер — аны башкага алмаштыруы өчен дә, улына күз-колак була алмавы өчен дә. Мәрьямбануның кимсетелеп, эшсез, ачлы-туклы яшәргә мәҗбүр булуы өчен дә — ул, Тимербулат үзе аннан кичерү сорарга тиеш бит!

— Нинди кичерү турында сөйлисең син, Мәрьямбану?! Мин үзем синнән кичерү сорарга тиеш бит! Менә Әхмәт исән-сау кайтсын да бер утырып сөйләшергә кирәк әле безгә. Болай булмый бит инде, булмый...

— Мин синнән бәхил, Тимербулат... Алдагысы Аллаһ кулында. Бәлки, сөйләшербез дә...

Тимербулат ишек төбенә килеп басты.

Озак кына бер-берләренә карап тордылар. Әйтерсең лә моннан дистә еллар элек беренче тапкыр очрашканнар... Һәм әйтерсең лә тагы дистә еллар күрешмәскә соңгы тапкыр очрашалар... Әйтерсең лә мәңгелеккә күрешмәскә, мәңгелеккә аерылалар...

— Кояш байый, Тимербулат...

— Минем өчен ул күптән баеды инде, Мәрьямбану...

Гәүдәсе ишек аша чыкты, җаны монда калды... Улының тәүге тәпи эзләре уелып калган бүлмәдә, зур, эчкерсез яратуның шаһиты булган бүлмәдә, гомеренең иң бәхетле чагы үткән бүлмәдә... Аңа бирегә кире кайту юлы юк иде инде...

Тимербулатның өенә, Римма янына керәсе килмәде. Хәер, нинди өе булсын инде ул аның, Тимербулатның өе менә монда, ишек артында калды. Римма янында ул — йортка кергән ир, Тимербулат та түгел — Тимур, монда бернәрсә дә Тимербулатныкы түгел. Алайса, нәрсә тота соң анда Тимербулатны? Менә биш ел үзенә шушы сорауны бирә инде Тимербулат. Әле һаман җавап таба алганы юк. Һәм таба да алмас, ахры. Сихер, дисәң, кеше кычкырып көләр, мәчет карчыгын-

нан качты, сихерчегә килеп капты, диярләр... Әмма бу шулай, нәкъ шулай. Сихерләде аны Римма, тимер кебек өрлектәй ирне телсез-өнсез колы итте, шәүләсе итте, сулышы итте. Тимербулатны элеккеге тормышыннан суырып алды да үзенә бәйләде дә куйды. Барысы да стенаның теге ягында калды — унбиш ел бергә яратышып яшәгән Мәрьямбану да, өзелеп яраткан бердәнбер улы Әхмәт тә, милли хәрәкәт тә, милләт үзе дә, дин дә... Барысы да ишекнең теге ягында калды. Бу йортта аларның берсе дә юк иде. Бу йортта Римманың мәңге бетмәс сихере, мәңге туйдырмас шашкын дәрте, ратуы, мәңгелек ялган һәм мәңгелек гөнаһ кына бар иде...

Бүген нигәдер Тимербулатның анда керәсе килмәде. Әллә нигә бүген ул да җанына урын таба алмый иде. Тәмам караңгы төшкәнче, урамнарны бер әйләнеп керергә булды. Һәрвакыттагыча, лифт эшләми иде. Тимербулат җиденче каттан әкрен генә аска төшә башлады. Күп этаж араларында ут янмый, шуңа күрә кармаланып, капшанып кына төшәргә туры килә. Аягы белән нәрсәгәдер басты, ахры, ачы итеп чыелдаган тавыш ишетелде. Чыннан да, аяк астында нәрсәдер кыймылдый, шуыша, хәрәкәт итә иде. Яктырак урынга чыккач, Тимербулат кычкырып җибәрә язды — җепкә тезелгән кебек, өске катлардан соры тычканнар төшеп килә иде! Тукта, монда стена да ниндидер бөҗәкләр, җан ияләре белән тулган бит! Барысы да, ниндидер әмергә буйсынып, аска — урамга ашыгалар иде. Нәрсә булыр бу, нинди сүзсез хикмәт-могҗиза? Тимербулат шулай дип уйлап өлгермәде, нәрсәгәдер абынып, сөрлегеп китте. Аяк астындагылар хахылдашып куйдылар. Караңгыда бераз күз ияләнгәч, Тимербулат почмакта өелеп утырган яшьләрне күрде. Үги улы Вова да алар арасында иде. Инде егермегә җитеп килә торган бу егет бер җирдә укымый да, эшләми дә. Наркоман бу егетнең бөтен гомере уколдан уколга миңгерәүләнеп, саташып, тартышып, йоклап үтә. Менә шундый фаҗигасе дә бар әле Тимербулатның яңа өендә, яңа тормышында. Бүген дә әнә үз ишләре белән төнге аугa, төнге кәефкә чыкканнар. Шулай кичтән чыгып китә дә таң алдыннан гына өстерәлеп кайтып егыла ул. Аннан көне буе йоклый. Әнисе эшли торган җиреннән, больницадан аңа дип шул миңгерәйткечләрне ташый... Тормыш түгел, мәхшәр... Тимербулат, күзләре аларган бу өернең өстеннән атлап диярлек чыгып, урамга атылды. Аяк астында әллә адәми затлар, әллә күсе-тычканнар, әллә башка хәшәрәтләр чинашып калды.

Урамда да инде тәмам караңгыланып килә иде. Тик бу әле төн караңгылыгы түгел, кара болытлар алып килгән иртә караңгылык, табигатьнең эңгер-меңгер бер чагы иде. Йөзгә бәреп-бәреп, усал җил исә. Биек катлы йортлар тирәсендә

җилләр бигрәк тә явызлана, кешене бөҗәк урынына таш стенага чәпәрдәй булып котырына. Тимербулат та, бу җил оясында кая барырга белмичә, шактый басып торды. Ул арада күрше подъезд төбенә милиция машинасы килеп туктады. Машинадан өчәү төштеләр дә ашыгып ишеккә юнәлделәр. Берсенең килеш-кыяфәте Тимербулатка таныш кебек тоелды. Башын җилкәләре белән капларга, яшерергә теләгәндәй, куырылып, газапланып атлый иде бу кеше. Менә ул кинәт кенә бу якка борылып карады. Һәм Тимербулат күрше егете Хәйдәрне танып, кычкырып җибәрә язды. Хәйдәр дә аны таныды, ахры, бер мәлгә туктап торган кебек тә булды, ләкин янындагы кешеләр аны этеп диярлек подъездга алып кереп киттеләр. Бераздан тугызынчы катта, Хәйдәрләр тәрәзәсендә ут кабынды. Тимербулат шактый гына көтсә дә, Хәйдәрне озата кергән милиционерлар кире чыкмадылар. Тимербулат, бу күргәннәре турында нәрсә уйларга да белмичә, борылып өенә кереп китте. Ул Хәйдәрнең кайдадыр укып, хезмәт итеп йөргәнен белә иде, тик нигә ул шулхәтле сак, күзәтү астында яши башлаган — Тимербулат аңламады. Хәер, Хәйдәр инде — ул бала вакыттан белгән Хәйдәр түгел, дөньялар да элеккеге дөнья түгел, кемне нәрсә өчен саклаганнарын да, яклаганнарын да һич аңлатырлык-аңларлык түгел иде…

* * *

Хәйдәр дә подъезд ишеге төбендә басып торган Тимербулатны күрде, янына барып, Әхмәт турында сөйләп бирәсе килде, әмма озата баручылар моңа ирек бирмәделәр, әйтерсең лә Хәйдәр җинаять кылган кеше, әйтерсең лә ул болар кулында әсир. Мәскәүдән самолет белән дә, җинаятьчене алып кайткан кебек, ике ягыннан саклап алып кайттылар, монда да өйгә хәтле китерделәр. Әсирдән аермалы буларак, кулларында богаулары гына юк Хәйдәрнең. Югыйсә ул да алар кебек үк бер милиционер бит, Чечняда булды, кушканны эшләде, кушмаганга катнашмады. Хәйдәргә карата бу саклык чараларын чеченнар белән бәйләп аңлаттылар. Имеш, ОМОНда хезмәт итүчеләргә, сатлыкҗаннарга карата алар аерата үчле икән, туган җирләренә кайткач та, аларны эзләп табып юк итүләре мөмкин икән… Хәйдәрне озата килүчеләр дә бүген өйдән беркая чыкмаска, беркем белән сөйләшмәскә, телефон шалтыратуларына җавап бирмәскә кушып, чыгып киттеләр. Телефон эшләми дә иде. Гомумән, өйдә әллә нинди сәер тынлык, шомлы билгесезлек иде. Җитмәсә, Фабарисов үзе Хәйдәр янына килеп чыгасын әйткән, өйдән бер җиргә аяк атламаска кушкан.

Хәйдәр әнисенең өйдә булмавына башта сөенеп куйды.

Яшелчә-җимешләр өлгергәндә, әнисенең айлар буе бакчада куныш, бакча каравыллап ята торган гадәте бар. Аларның бар карап торганнары шул бакча бит. Фабарисов теге вакытта әтисен төрмәдән чыгарырга вәгъдә иткән иде, әтисе дә һаман күренми. Әйтерсең лә әле егермесе яңа тулган Хәйдәр бу дөньяда япа-ялгызы. Кечкенәдән күңелендә бер якты нур бар иде, ул — аның Ләйләсе иде... Ул Ләйләне мәктәп елларыннан яратты, башка беркемне күрмәде, күрәсе дә килмәде, ул Ләйлә белән генә авырган, Ләйлә дип кенә саташкан иде. Ә Ләйлә Әхмәтне сайлап алды. Әгәр Әхмәт исән булса, алар хәзер бергә булырлар иде. Шуңа күрә дә тегендә, таулар арасында үлеп яткан Әхмәт янына бармады Хәйдәр, аны коткарып калу өчен берни дә эшләмәде. Хәер, ул нәрсә эшли алган булыр иде соң? Анда ул татар егетләренә беркем ярдәм итәрлек хәлдә түгел иде, алар ике ут арасында калдылар...

Хәйдәрнең бүгенге тормышы әллә нинди серләрдән һәм хәвефләрдән тора. Бу ыгы-зыгыларга әнисен дә, беркемне дә катнаштырасы килми Хәйдәрнең. Әле нәрсә булганын ул үзе дә яхшылап аңлап бетермәде, шуңа күрә Хәррис Фабарисовны көтә. Хәйдәрнең Фабарисовка бик күп сораулары бар. Бу егетләрнең үлемендә Фабарисовның гаебе бармы, нигә ул Хәйдәрне Чечняга башта — мөселманнар арасына, аннан — аларга каршы корал тоттырып җибәрде? Чечнядагы чын хәлне Фабарисов беләме, ул да татар егетләрен чеченнар үтерде дигәнгә ышанамы? Хәйдәр бүген боларның барысына да җавап алырга тиеш. Хәйдәрнең җанын бер генә нәрсә борчый — бу фаҗигадә аның катнашы, гаебе бармы? Шушы сорауга җавап тапмыйча, аңа яшәү юк. Менә күпме вакыт куллары бәйләнгән утыз сигез татар егете, тәкбир әйтеп, һәр төн аның каршында аягүрә үлә! Каргап, бәддога укып, ләгънәтләп үлә... Алар арасында Әхмәт тә бар. Аның бердәнбер балачак дусты һәм көндәше...

Кодрәтеннән килсә, Хәйдәр Чечняда күргәннәрен, ни эшләп йөргәннәрен мәңгегә онытыр иде, ул аларны онытырга тели. Әмма утыз сигез татар егете оныттырмый, һәр көн, һәр төн, күзгә карап, җавап көтәләр. Ә җавапны Хәйдәр үзе дә белми, шунлыктан аңа икеләтә авыр, икеләтә газап иде. Юк, Хәйдәр үз кулы белән берәүне дә үтермәде, теле белән берәүне дә сатмады, ул бары тик нәрсә кушсалар, шуны эшләде, кая җибәрсәләр, шунда барды. Ул Фабарисовка Ходайга ышанган кебек ышанды, ул аңа атасын да, ир туганын да алыштырды. Ул Хәйдәрне төрмәдән алып калды, башта мәдрәсәгә, аннан, Хәйдәр үзе теләмәгәч, мәдрәсәдән алып милиция мәктәбенә кертте, әтисен төрмәдән чыгарырга вәгъдә итте, әнисен эшкә урнаштырды. Югыйсә Фабарисов алар өчен җиде ят иде бит, ә гомер буе күзәтеп, ярдәм итеп торды. Фа-

барисов әйтүе буенча, Чечняда Хаттаб лагеренда берничә ай укып кайту Хәйдәр өчен бер кызык кына булды, ул аңа уен итеп кенә карады. Аннан шул ук Фабарисов аны ОМОН составында Чечняга озатты, монысы инде бик үк кызык түгел иде, әмма качып котыла торган эш тә түгел иде.

Чечняда чагында ук инде Хәйдәр үзенең кемнәрдер кулында уенчык икәнен сизенә башлады. Аның белән, аның тирәсендә нindидер уен бара иде, әмма бу уенның ни дәрәҗәдә мәкерле, ни дәрәҗәдә куркыныч икәнен Хәйдәр әсирлеккә төшкәч кенә белде. Бу канлы уенны, аны башкаручыларны үз күзләре белән күрде Хәйдәр, чеченнар түгел иде алар... Аннан — бу татар егетләре фаҗигасе. Чеченнар Хәйдәрнең күз алдында утыз сигез татар егетен атарга алып чыккач кына, ул бу канлы уенның серен аңлады. Чеченнар барлык татарларны да хыянәттә гаеплиләр иде. Үлем каршында басып торганнарын да, Хәйдәр кебек үлемнән качып ятканнарын да. Һәм аларның болай уйлавында Хәйдәрнең дә катнашы бар, Хәйдәрнең дә гаебе бар иде... Ләкин моны Хәйдәр бик соң — татар егетләре үлем каршына тезелеп баскач кына аңлады...

Хәйдәр үз күзләре белән күрде — үтерергә алып чыксалар да, татарларга чеченнар атмадылар. Ул моны теләсә кем алдында кабатлый ала. Һәм ул аны сөйләргә дә тиеш. Менә монда, илендә, үз милләттәшләренә, бу егетләрнең ата-аналарына бар хакыйкатьне сөйләп бирер Хәйдәр. Теләсәләр, алар хөкем итәрләр аны, теләсәләр — акларлар. Әмма бу фаҗигане Хәйдәр берьялгызы күтәреп йөри алмаячак. Бу гаебен, бу гөнаһын аңлаган мизгелдән, Хәйдәр эчтән җимерелә, сүтелә башлады. Әйтерсең лә тәнендә һәм җанында һәркөн йөзәрләгән күзәнәк үлә, йөзәрләгән шәм сүнә. Бу кадәр дә зур ялганны, бу кадәр дә зур мәкерне, фаҗигане ул инде ялгызы гына күтәреп бара алмасын аңлады. Ул чын дөресен кешеләргә сөйләргә тиеш иде.

Мәскәүдә, телевизордан оештырылган тапшыруда, ул дәшмәде. Чөнки аны тормыш бераз сак булырга, мәкер корбаны булмаска өйрәтә башлаган иде инде. Ул чын дөресен сөйләсә, аны телевизордан күрсәтмиләр генә иде, ә үзен юк итәргә җай табарлар иде. Бөтен дөреслек Хәйдәр белән бергә юкка чыгачак, милләт йөзенә сатлык дигән кара тап йогылып калачак иде. Шуңа күрә егет анда дөресен әйтергә ярамаганын аңлады. Шуңа күрә ул менә бирегә, үз иленә, үз милләттәшләре арасына дөресен сөйләү өчен кайтты. Телиләр икән, аны хыянәтче, провокатор дип атасыннар, әмма татар милләте бу кара исемне күтәрергә тиеш түгел. Менә бу төн генә үтсен, Фабарисов белән ачыклыйсы нәрсәләрне ачыклап бетерсен, аннан ул Әхмәтнең әти-әнисенә дә, башкаларга да чын

дөресен әйтер. Ләйләгә дә Әхмәтнең соңгы сәгате турында сөйләр, барысы өчен дә кичерү сорар, кичерүләрен сорар.

Хәйдәр әнә шундый кискен карарга килде. Ул төн үткәнен көтте. Әмма үзе өчен бу төннең соңгы төн икәнен ул әле белми иде...

***Үрмәкүч үзенең бу ау-җәтмәсен озак үрде. Башта пәрәвез белән булачак тозакның тирә-юнен әйләндереп алды, аннан урталыкны ябышкак җепләр челтәре белән каплады. Бу эшләрне башкарганда, сигез аягы һәм сигез капшавычы туктаусыз хәрәкәттә булды, тәнендәге бизләр тозак өчен лайла әзерләп торды. Үрмәкүчнең тәнендәге барлык әгъзалары, бөтен тормышы бары тик пәрәвез үрергә һәм аңа эләккән корбанын агулап үтерүгә генә көйләнгән иде. Үрмәкүч башкача үзенә азык таба алмый, әгәр пәрәвез үрүдән туктаса, ул һәлак булачак иде... Ул бары тик шушы рәвешле генә нәселен дәвам итә ала иде...***

***Үрмәкүчнең менә бу җәтмәсенә дә тиздән кем дә булса төшәр... Үрмәкүч аның лайлалы җепләргә уралганын көтеп-күзәтеп торыр да, корбаны пәрәвезгә төшкәч, капшавычларын аңа батырыр, корбанының тәненә иплән кенә агуын җибәрер... Бу агу пәрәвезгә эләккән җан иясенең бөтен эчке әгъзаларын җимереп ташлар, кайнатыр һәм Үрмәкүч өчен шифалы сыекчага әйләндерер... Үрмәкүч, беркем артыннан йөгермичә, кумыйча, гомерен куркыныч астына куймыйча, бары тик мәкер көченә генә таянып, ризыклы булыр, исән калыр, нәселен дәвам итәр...***

***Менә Үрмәкүч үзенең җәтмәсен үреп бетергән инде...***

***Менә тиздән аңа беренче корбан кабар...***

***Хәзергә Үрмәкүч селкенмичә дә шул корбанын көтә... Теш казналарындагы агуы һәрчак тулы һәм әзер аның...***

Хәррис Фабарисов бу көннәрдә тормышының иң мәгънәле, иң әһәмиятле, иң җитди бер чорын кичерә. Ул гомере буе куркынычсызлык органнарында тугрылыклы эшләгән кеше, шушы кечкенә генә бер шәһәрдә, зур булмаган чинда, күрелмәгән һәм тиешле бәясен алмаган килеш инде пенсиягә дә китеп барган булыр иде. Әгәр яңа чечен сугышы башланмаган булса... Әгәр Россиядә мөселман-ваххабиларга каршы көрәш күтәрелмәгән булса. Ул чагында полковник Фабарисов инде пенсионер Фабарисовка әйләнгән булыр иде. Шушы хәлләр башланды — әллә кайда, кечкенә бер татар шәһәрендә шыпырт кына эшләп яткан Фабарисов та Мәскәү өчен иң кирәк кешеләрнең берсенә әйләнде. Менә бүген дә Мәскәүдән ФСБ генералы үзе ничә тапкыр шалтыратып, мондагы эшләрнең барышын сорашты, киңәш-әмерләрен бир-

де. Бу үзгәртеп корулар башлангач, үзе кебекләр белән бер читкә чыгарып ташланган, кимсетелгән, онытыла башлаган полковник өчен моннан да зур мәртәбә, моннан да зур дәрәҗә була аламы соң?! Соңгы вакытта Фабарисов бөтен күзәнәк-тамырлары белән шуны сизенә — алар яңадан кирәк була башладылар! Алар илгә яңадан кирәк! Аларның акылы, тәҗрибәсе бу илгә тагы кирәк! Шул үзгәртеп корулар башланып, КГБ кирәксез бер нәрсәгә әйләнмәгән булса, бу акылы һәм сәләте белән Фабарисов күптән инде йә Казанда, йә Мәскәүдә утырган булыр иде. Тормышының ун елы, гөрләп үсә торган, хезмәт итә торган, дан-дәрәҗәләр яулый торган чоры милләтчеләрнең телефоннарын тыңлап, артларыннан шымчылык итеп, аларны үзара талаштырып-сугыштырып, җыен юк-бар белән үтте. Милли хәрәкәт Фабарисов көткәннән дә тизрәк бетте, артларыннан шымчылык итәрдәй кеше дә калмады, алар бетү белән Фабарисовка да эш бетте, аның да югарыдагылар өчен кирәге юк иде инде. Һәм менә бу хәлләр... Дагестан, Чечня, Мәскәүдә шартлаулар, мөселман-ваххабилар, «Йолдыз» мәдрәсәсе, Кукмарада газ торбалары шартлаулар... Бу вакыйгалар, бөтереп, Фабарисовны да үз эчләренә алып кереп киттеләр. Мәскәү өчен Фабарисов иң кирәкле, иң кыйммәтле кешеләрнең берсенә әйләнде. Фабарисов, карт чекист, сизде — Мәскәүдә үрелә башлаган мәкерле пәрәвезгә аның кебек йөзләгән-меңләгән шымчыларның да ярдәме, агуы кирәк иде...

Мәскәүдән Хәррискә пәрәвез җебенең очын гына күрсәттеләр — монда җәтмәне Фабарисов үзе үрергә тиеш иде. Һәм ул шулай эшләде дә — башкаларның язмышларына урый-урый, бөтен осталыгын, сәләтен һәм мәкерен салып, пәрәвезне үзе үрде... Соңгы елларда үзенең хаксызга тибәрелүенә ачу итеп, зыялы әфәнделәрнең аның кебекләр хезмәтенә җирәнеп карауларына үч тотып, үзенең шымчы түгел, бөек сәясәтче икәнен исбатларга омтылып, полковник Фабарисов илне кирәксез элементлардан арындыру буенча Мәскәү белән бергә тиңсез бер план корды. Һәм менә ул бүген, шушы яшерен эшләр башлануга берничә ел дигәндә, хезмәтенең җимешләрен дә күрә — аның белән Мәскәү генераллары сөйләшә, Фабарисов белән Мәскәү генераллары исәпләшә! Кем әйткән иде бу карт стукачка инде пенсиягә вакыт дип, кем әйткән иде аның нәселе төрмәдә черичәк, тәмугта яначак дип?! Алар бүген үзләре Фабарисовлар төрткән тәмуг утларында яналар, алар бүген үзләре, Фабарисовлар котыртуы буенча, бер-берләренә аталар, алар бүген үзләре пәрәвезгә эләккән чебен кебек чәбәләнәләр... Кайда бүген синең улың, Мәрьямбану?! Горур, баш бирмәс Мәрьямбану, милләтче Мәрьямбану, Коръәнче Мәрьямбану?! Кайда «Бәйсез-

лек!» дип кычкырып үскән балаларыгыз, кайда бәйсезлегегез, кайда бөек максатларыгыз?! Имеш, Татарстанны гына түгел, Чечняны да бәйсез итәләр, имеш, мөселманнарны кяфер коллыгыннан коткаралар! Россия хәтле Россиягә кул күтәрәләр, тел тидерәләр!!! Теге еллар булса, алар инде әллә кайчан юләрләр йортларында һәм төрмәләрдә черерләр иде… Уен бетте, әфәнделәр! Һәм сезнең файдага түгел…

* * *

Барысы да милли хәрәкәттән башланды… Мәрьямбануны да менә шушылай якыннан, ут-ялкын кыяфәтендә, Фабарисов беренче булып милли хәрәкәт җыелышында күрде. Хәррис милләтчеләр арасына тиз кереп китте — җыелышларына йөрде, митинг-пикетлары тирәсендә баскалап торды, аларга ияреп анда-монда барды. Ул беркайчан да үзенең кайда эшләгәнен яшермәде, шул ук вакытта ул хакта чат саен кычкырып та йөрмәде. Әйе, без барыбыз да татарлар бит, бер-беребездән яшерен серләребез юк, бер-беребезгә зыян салыр ниятебез юк, шуңа күрә бердәм булырга кирәк, — әнә шундыйрак иде аның тел төбе милләтчеләр белән сөйләшкәндә. Милләтчеләр, беркатлы халык, аларның, чыннан да, Фабарисовтан яшерен серләре юк иде, башларына нинди уй килсә, шуны урамга чыгып кычкыралар, язып чыгалар, шул кәгазьләрен күтәреп, җитәкчеләр янына баралар. Фабарисов мондый беркатлы урам сәясәтенең озакка бармаячагын бик тиз аңлады, милли хәрәкәт тарафыннан беркемгә дә куркыныч янамавын да белә иде ул, шулай да күзәтүләрен дәвам итте.

Менә шундый җыелышларның берсендә ул беренче тапкыр якыннан Мәрьямбануны күрде. Дөрес, аның бу хатынны элек тә шәһәр активы җыелышларында күргәләгәне бар иде, ул аның педагогия техникумында директор булып эшләвен дә белә иде. Шуңа күрә Мәрьямбануны милләтче карчыклар арасында күрү аңа бераз сәеррәк булып тоелды, чөнки җитәкчелектә эшләүче татарлар, гадәттә, мондый җыелышларга йөрмиләр иде. Елкылдап торган кара чәчләрен татар хатыннарына хас рәвештә артка җыеп куйган, йөзләре алсуланып янган бу гүзәл хатынны техникум директоры дип таныштыргач, зал гаҗәпләнеп гөжләп куйды. Биредә чыгыш ясаучылардан аермалы буларак, бик җитди һәм дәлилле итеп, ул техникумда татарча укытуның торышы турында сөйләде, закон чыкканны көтеп ятмыйча, бу өлкәдә нәрсәләр эшләгәннәрен әйтте. Баксаң, биредә бөтен тәрбия эшләре, директор уздырган җыелышлар, хәтта кәгазь-документлар күптән татарча алып барыла икән, инде укытуның программасын

үзгәртергә министрлыктан рөхсәт көтәләр икән! Мәрьямбану шул мәсьәләне тизләтүдә милли хәрәкәттән ярдәм сорады.

Хәррис, бу хатын өчен татар буларак эчтән сөенеп, горурланып куйса да, аның авызыннан яңгыраган артык милли, милләтчел сүзләргә колагын сагайтты. Ай-һай, артык нык бөгә түгелме икән бу хатын? Ул коллективта бит әле урыслар да эшли, алар ни әйтерләр? Әлбәттә, каршы киләчәкләр, кемнең тел дип эшсез урамда каласы килсен? Һәм, менә шулай итеп, милләтара ыгы-зыгы әзер дигән сүз. Хатлар, жалобалар китәчәк, Казанына да, Мәскәвенә дә. Моның өчен, әлбәттә инде, Фабарисовның башыннан сыйпамаслар. Димәк, бу хатынның артык эшчәнлеген, активлыгын тыя төшәргә, кирәк икән, туктатырга ук кирәк. Әмма әмер белән, турыдантуры комачау итеп түгел, ярдәм итмичә туктатырга кирәк бу эшне, ягъни шушы проблемалары белән берьялгызларын калдырырга, кирәк икән, өстәмә проблемалар да тудырырга кирәк. Йөрер-йөрер дә арып туктар бу хатын...

— Менә сез, ханым, — дип сорау бирде Хәррис әдәпле генә, — менә сез тоташ татарчалаштыру, дисез. Аның, беренчедән, укыту өчен милли кадрлары булмаячак, икенчедән, татарча дәреслекләр юк. Ул проблемаларны бит болай ордымбәрдем, бер-ике көндә генә хәл итеп булмый. Аңа еллар кирәк, дистә еллар...

Зал бу сүзләрдән, ризасызлык күрсәтеп, гөжләшә башлады. Кайсыдыр кайнар башы, чәчрәп торып, чыгыш ясарга тотынды:

— Әнә үзбәк-казах каян кадр тапкан? Каян дәреслекләр алган?! СССРдан аерылып та чыктылар, икенче көнне үк үзләренчә укыта да башладылар. Ә эш безгә килеп терәлгәч, кадр юк, дәреслекләр юк, имеш! Бар, барысы да бар, татар кебек бөек милләттә ул дәреслекләр революциягә хәтле үк булган инде. Аларны күтәреп карарга гына кирәк.

Зал гөрләтеп кул чаба башлады. Мәрьямбану онытылды, ул күтәргән проблемалар бер читтә калды. Милләтчеләр кызып-кызып бәхәсләшергә тотындылар — казах башлыракмы, татармы, кем кемнән укыган, белем алган... Хәррис өчен бу да яхшы иде, тилереп кул чапсалар чапсыннар, мактансалар мактансыннар, тик артык тирәнгә генә кермәсеннәр. Парлары шушында чыгып бетсен. Өйләренә зур эш башкарган кебек кайтып китсеннәр. Татарча укыту кирәкме-юкмы, ул хакта югарыдагылар уйлар, ә астан болгата-болгана башласалар, монда да Карабах буласын көт тә тор.

Әмма Мәрьямбану да югалып кала торган хатын түгел икән. Тәҗрибәле җитәкче буларак, ул сүзнең башка юнәлешкә кереп киткәнен тиз тотып алды, бу махсус болгатуда Фабарисовның да катнашы барлыгын аңлады:

— Кадрлар мәсьәләсенә килгәндә, — диде ул Хәрриснең күзләренә батырып карап, — без ул милли кадрларны үзебез әзерлибез. Безнең элеккеге студентларыбыз, институтлар, аспирантуралар тәмамлап, бүген-иртәгә безгә кайтырга торалар. Без алар белән элемтәне беркайчан да өзмәдек һәм алар бүгеннән милли белем бирүне үз өсләренә алырга әзерләр. Ә инде дәреслекләр мәсьәләсенә килгәндә, чыннан да, эш катлаулырак. Төгәл фәннәр генә түгел, хәтта тарих, география дәреслекләре дә — барысы да урыс телендә. Монда безгә галимнәрнең ярдәме нык кирәк булачак. Дөнья бик нык алга китте, хәзер революциягә кадәр язылган дәреслекләр белән генә эшләп булмас. Кайбер дәреслекләрне татар телендә мин үзем дә әзерләштем. Әйтик, биология буенча мин язган дәреслек министрлыкта хуплау үтте, хәзер ул нәшриятта басылып ята. Техникумда тарих һәм география буенча татарча дәреслекләр әзерли башладык. Бәлки, биредә утыручылар арасында да безгә ярдәм итәргә теләүчеләр табылыр? Рәхим итегез, бергә-бергә эшләрбез.

Менә шулай итеп, Мәрьямбану Хәррисне үз урынына утыртты да куйды. Габарисов бу хатынны болай гына җиңеп, чигендереп булмасын бик яхшы аңлады. Ул гыйлемле иде, тәҗрибәле иде, әмма иң мөһиме — ул башкалар кебек сөйләп кенә калмый, әйткән сүзен үзе эшли иде. «Һәм искиткеч чибәр, һушны алырлык чибәр, каһәр» дип эчтән генә уйлап куйды Габарисов. Мондый хатыннар үз көчләренә нык ышанып эш итәләр шул һәм максатларына ирешми калмыйлар. Ул чагында Габарисов тирәнгә кереп тормады, әйдә, маташсыннар, өстән кушалар икән, Габарисов бу милләтчелекне туктатыр, юк икән — бик үк катнашып китмәс. Әмма бу үткен хатынны хәзер күздән ычкындырмас Габарисов, азу ярган милләтче булганы өчен генә түгел, аңнарны җуйдырырлык гүзәл, ымсындыргыч булганы өчен дә... Бу уйларын Габарисов бик тирәнгә, хәтта үз-үзеннән дә яшерде, гомерендә беренче тапкыр өстән кушу буенча түгел, эчтән кушу буенча хатын-кыз артыннан күзәтә, күзли башлады...

Җыелыш бетү белән, әллә бу хатын турында күбрәк беләсе килеп, әллә бу хәтле камил гүзәллеккә якынрак торасы итеп, үзе дә аңлап бетмәгән җилкенү-ярсу белән Габарисов Мәрьямбану янына ашыкты. Мәрьямбануны халык сырып алган иде. Йөзеннән якты нур сирпеп торган бу хатынга һәркем якынрак килергә тырыша, кирәксә-кирәкмәсә сүз әйтә, сорау биргән була. Габарисов, әби-чәбине ерып, Мәрьямбануга якынлашты, якынлашкан саен, үзендә әллә нинди сәер рәхәтлек, каушау, бу хатынга ихтыярсыз тартылу тойды. Бу хис Габарисов өчен таныш хис түгел иде, әмма аның үзеннән бу изрәткеч рәхәтлекне куасы, аннан арынасы килмәде.

— Сез бик кыю чыгыш ясадыгыз, — диде ул, Мәрьямбануның күзләренә кереп калырга теләгәндәй.

Мәрьямбану да аптырап калмады:

— Без шулай кыю эшлибез дә, абзый, — диде бөтен йөзен нурландырып, үзе тагы елмайды.

Абзый дигәненә бераз хәтере калса да, Мәрьямбануның, ят итмичә, шулай иркенләп үзе белән сөйләшеп торуына сөенде Фабарисов. Югыйсә аның кайда эшләвен белгәч, күпләр чит итә, сөйләшми, бөтенләй әйләнеп үтүчеләр дә бар. Фабарисов, тасма телләнеп, тагы сүзне озайтмакчы иде, халык арасыннан кыядай калкып, бер әзмәвер ир пәйда булды. Ул Фабарисовны терсәге белән генә бер читкә этеп, Мәрьямбануны култыклап алды.

— Кайтыйк, әнисе, бетмәс монда шымчы картлар... Ә син, абзый, бар, юлыңда бул!

Фабарисов тимгел-тимгел булып кызарынды, пеләшенә тир бәреп чыкты. Ул арада халык, этенә-төртенә, залдан чыга башлады. Мәрьямбану, гафу үтенгән кебек, Фабарисовка карап куйды да, иренә сыенып, урамга чыгып китте. Фабарисов аларның артыннан озак карап торды. Алар яшьләр иде, алар тиң килгән, алар янәшә барганда көчле һәм куркусыз иде...

Фабарисовны бүген хатын-кыз алдында икеләтә кимсетләр — картлыгына да, органнарда эшләвенә дә төрттерделәр... Аһ, теге еллар булсамы, бу сүзләрне әйткән өчен? Фабарисов эчендәге бөтен уты-ялкыны белән сызланып, ыңгырашып куйды. Теге еллар булсамы? Бу сүзләрне әйтергә батырчылык итмәсләр иде бу адәм актыклары. Әйтсәләр, урыннары дурдомда, төрмәдә булыр иде, кул-аяклары бәйләп ташланган хәлдә... Фабарисовның яңак сөякләре уйнаклап алды, ясалма тешләре казнасы-ние белән шыгырдап куйды. Ул үзенең бүген кичергән хурлыгын мәңге онытмаячак иде...

Менә бүген алар янәшә киттеләр, ә иртәгә тормыш аларга әллә нинди хәлләрен китереп чыгарырга мөмкин бит. Ә нигә тормыштан көтәргә? Мондый мәхлукларның Тәкъдир китабына үзгәрешләр кертү аның өчен хәзер дә кыен эш түгел. Әллә алар Фабарисовларның көне беткән дип уйлыйлармы? Дөнья беткәндә дә Фабарисовлар бетмәячәк, Фабарисовлар кирәк булачак. Һәм бу тәкәббер милләтчеләргә дә моны исбат итәчәк Хәррис, исеме белән ант итеп әйтә, исбат итәчәк... Шуңа бөтен гомере үтеп китсә дә, күпләрнең Тәкъдир китабы аның кулында икәнен ул барыбер исбат итәчәк...

* * *

Римма Тимербулатның кинәт кенә кубарылып чыгып китүен күрде, әмма аны туктатырга кирәк тапмады. Бу минутларда Риммага барыбер иде — чөнки ул бүген үзенең үлемгә хөкем ителгәнен белде. Бүген Риммада СПИД таптылар... Башта улында — Вовада таптылар, шунда ук Римманың да анализларын алдылар. Һәм менә алар аналы-уллы икесе дә хурлыклы, газаплы үлемгә дучар ителделәр... Кем тарафыннан, нәрсә өчен?! Римма, шул кара көчне тотып бугазларга теләгәндәй, бүлмәдән бүлмәгә атылды, бер почмакта чинап утырган Сигналны тибеп очырды, Вованың өстәленнән бөтен шприцларын, төнәтмәләрен бәреп төшерде, ярсып, нәрсәдер эзләде, нәрсәгәдер һөҗүм итте. Әмма ул кара көчнең үз эчендә бөгәрләнеп утыруын, кан тамырлары буенча котырып чабуын, инде аны гына түгел, бөтен тирә-юнен дә агулый баруын белми иде әле бу хатын. Аның каны гына түгел, тәне, җаны да агуланган, күгәреп чыккан иде, бу — тереләй черү, аягүрә үлем иде, һәм үзенең шушы һәлакәтен Римма үз күзләре белән күреп үләргә тиеш иде...

Римма — меңнәр һәм миллионнар кебек катнаш каннан, катнаш никахтан, катнаш милләтләрдән барлыкка килгән динсез, милләтсез бер бәндә иде. Аның әнисе — марҗа, әтисе — керәшен татары, Римма үзе исә керәшен әбисеннән сихер серләренә өйрәнгән, күрәзәчелеге белән бөтен тирә-юньгә дан алган табиб-экстрасенс хатын иде. Бөтен дөньяга гөрләгән чаклары бар иде Римманың, бар иде! Аңа шәһәр башлыклары гына түгел, хәтта Казаннан, Мәскәүдән зур-зур кешеләр килә иде, шәхси тормышларында, бизнеста, сәясәттә дә җитди мәсьәләләрен аның белән сөйләшәләр, яшерен серләрен аңа гына ачалар иде. Депутат булып каян чыгарга яхшырак, кемнәр куркыныч көндәш булырга мөмкин, алардан нинди юллар белән арынырга — боларын да әйтә, өйрәтә иде үзенә килгән зур кешеләргә Римма. Үтмәстәй булса да әйтә иде, монда көчеңне әрәм итеп йөрмә, шул кеше янына бар, алга таба шул кешегә таян, яки бу кешедән саклан, дип тә әйтеп җибәрә иде. Аның турында дөресен әйтә, дигән хәбәр бөтен тирә-юньгә таралды, шушы дан белән, данга ияреп килгән байлык, дәрәҗә белән картайганчы тыныч кына яшәргә, рәхәт күрергә дә була иде бит... Тормышына Тимербулат килеп керү белән, барысы да буталды, асты өскә килде, тормыш Тимербулатның тәне һәм җаны өчен, бары тик аныкы гына булсын өчен туктаусыз көрәшкә әйләнде. Җиңелмәс, үзенекен бирмәс өчен Риммага инде керәшен әбисе өйрәтеп калдырган сихер серләре генә җитми башлады. Ул шайтанның үзе белән килешүгә керде...

Римма улының атасы кем икәнен белми. Ул чагында әле Римма ут чәчеп торган яшь бер кыз иде. Шәһәр шифаханәсендә аның кебек шәфкать туташлары күп булса да, үзенең кыргый матурлыгы, ташып торган дәрте, ачыклыгы белән ул башкалардан бик тиз аерылды. Моның өстенә кулы җиңел, уколны йомшак ясый, карашы шифалы дигән даны да тарала башлады. Берничә авыруга үзе генә белгән алым белән массаж да ясап җибәргәч, бу яшь кызның кулларындагы хикмәт турында хәбәр бөтен больницага таралды. Аны зур түрәләр яткан палаталарга махсус чакыртып, массажлар ясата башладылар.

Ялгыз бүлмә, зур түрәләрнең эштән һәм эчүдән йончыган көпшәк тәннәре һәм аларга бөтен дөнья мәшәкатьләрен оныттырган, изрәткән, сихерләгән яшь шәфкать туташы... Соңыннан ул үзе дә бу аерым хезмәт күрсәтүләргә иярә башлар, зур түрәләр янына да сайлап кына, үз дәрәҗәсен белеп кенә керә башлар... Шушы дәвалау вакытларында үзенә кирәкле күп эшләрне хәл итеп булганын да аңлар бу үткен керәшен кызы... Аның зур дөньяны яулавы менә шушындый кечкенә, аулак бүлмәләрдән башланыр...

Римманың әбиләре авылында яратып йөргән егете дә бар иде, яратуның нәрсә икәнен белеп калды ул. Мөгаен, дөньяда иң матур ир-атны яраткандыр ул... һәм иң айнымас кешене... Бу кечкенә керәшен авылында сирәк очрый торган шундый ир-ат матурлыгын күреп, күпләр гаҗәпләнә иде. Хәер, бу авылда кешеләр гаҗәеп матурлар, сылу гәүдәле, моңлы тавышлы иделәр. Һәм барысы да дип әйтерлек исерекләр... Бу керәшен авылында балалар туганда ук сөт шешәсе түгел, көмешкә тотып туалар иде, ахры. Авылда яшьләр бигрәк тә матур, сылу иде. Бит алмалары алсуланып янып торган, кара, тирән күзләреннән бетмәс наз һәм моң түгелгән керәшен егетләре һәм кызлары яшь чакларында теләсә кемнең башын әйләндерерлек, теләсә кемне аяктан егарлык булалар иде. Әмма туктаусыз эчү, гаугалы, талаш-ызгышлы авыр тормышта яшәү бу гүзәлләрдән бик тиз бөкре карчыклар, гарип, мәңге айнымас ир-атлар ясый иде. Менә шушы авылның иң гүзәл һәм иң сәрхуш егетен яратты Римма, атна саен атылып аның янына кайтты, тәне һәм җаны аңа тартылганга, аны теләгәнгә кайтты. Егетнең мәңге айнымаслыгын да белде, әмма үзе белән берни эшли алмады, бөтен яшьлеген, бөтен саф хисләрен аңа бирде... Бәлки, егеткә аякка басарга ярдәм итәрмен дигән яшерен өмет тә булгандыр, бәлки, шашкын тәненә һәм җанына кирәкне генә алырга йөргәндер, хәзер Римма инде хәтерләми. Әмма тиздән аны бу авыл пычрагында, исерек куенында аунау туйдыра башлады, ул керәшен егетеннән дә әкренләп туйды, бизде. Аннан башкалар китте. Бө-

тенләй башка шартлар... Зур, чиста аулак бүлмәләр, зур, дәрәҗәле абзыйлар. Барысы да бер чорда, кисәк кенә булды, барысы да буталды, әһәмиятен югалтты. Шуңа күрә улының атасын да тәгаен генә белми ул. Бәлки, шул эчеп үлгән керәшен егетедер, бәлки, Риммага менә шушы фатирны алып биргән шәһәр хуҗасыдыр, бәлки, башкалардыр... Моның Римма өчен бернинди әһәмияте дә юк иде инде. Гомумән, тормышында Тимербулат очраганчы, Римма ир-атларга бер кәсеп чыганагы итеп кенә карый башлаган иде инде. Беренче мәхәббәте айнымас исерек булды, калганнары айный торган исерекләр, азган бәндәләр иде, Римма — аларга, алар Риммага бер товар кебек кенә карадылар. Римманың тормышында ярату-мәхәббәт сүзләре дә булмады, юньле кеше аңа өйләнергә тәкъдим дә ясамады. Юньсезе исә Риммага кирәк түгел иде. Гомеренең уртасы җитеп килгәндә, инде бу килгәнкиткән ир-атлардан тәмам туеп, ялгыз картлыгына кереп барганда, ул Тимербулатны күрде. Башта — бу кешегә карата тиңсез нәфрәт, аннан саташыр хәлгә китергән мәхәббәт Римманы мәңгегә Тимербулатка бәйләп, мәңге аерып ала алмаслык итеп беректереп куйды. Инде менә Тимербулатны мәңгегә үземнеке иттем дигәндә — шушы хәбәр. Римма беркем аера алмас дигән иде, арага үлем чире килеп керде. Римма бу чирнең, чалгы тотып, кан тамырлары буйлап чабуын сизә, бу чир аның йөрәгенә, миенә үрмәли, җелеген суыра, бавырбөерләрен ашый... Шундый ук афәт улы артыннан йөгерә, ул инде аны элеп киптерде, саргайтты, тере мәеткә әйләндерде. Вова наркотиклар белән генә тора, Римма туктаусыз шул үлем юлдашын табып тормаса, бала күптән яткан җиреннән тормас иде. Хәер, аның торуыннан, яшәвеннән дөньяга нинди файда да, нинди зыян? Бу хәбәрне алгач, Римманың да күңеле катты, шушы дала кадәр өйдә, мал-байлык арасында улы белән икесенең тиздән череп үләсен күз алдына китерү аны шашындыра, ярсыта, күккә карап үкерер хәлләргә китерә иде. Нигә?! Нигә аны — Римманы сайлады бу чир? Әллә Тимербулат өчен шушы җәза, каргыш булдымы? Әбисенең өрәге кисәтте бит аны — бу эшне эшләмәскә кушты, бәддога төшәчәк, диде. Әмма Римманы туктатырлык түгел иде инде.

Башта Тимербулатны бөтен күзәнәкләре белән куралмады Римма. Бу фанатик милләтчеләр белән күрше булуына хурланды, җенләнде, шартлар дәрәҗәгә җитте. Ничек инде ул, кырыкка җиткәндә, байрак күтәреп, урамда акырып-бакырып йөрергә мөмкин?! Беренче тапкыр үзенең күршеләрен мәйданда плакат күтәреп торуларын күргәч, Римма артка авып китә язган иде! Берсенә тел кирәк, берсенә дин кирәк, дәүләт кирәк икән! Өчәүләшеп басып торалар, хәтта улларын өстерәп алып чыгарга да тартынмаганнар. Кемнәр

белән күрше булуын белгәч, башта Римма квартирасын алмаштырырга, бу котырган милләтчеләрдән котылырга уйлаган иде. Әмма язмыш башкача язылган булган, күрәсең. Болардан китү, качу гына түгел, үзе суырылып шушы гаиләгә килеп керде, аны җимерде, үзенә кирәген алды, үзенчә эшләде. Хәер, үзенчә генәме? Әгәр шул вакытта Фабарисов очрамаган булса, Римманың тормышы хәзер кайсы юлдан киткән булыр иде икән? Һәрхәлдә, анда Тимербулат булмас иде, ә Тимербулаттан башка тормыш үзе дә булмас иде...

Фабарисовның хатыны үзеннән җиде-сигез яшькә олы, бик чирләшкә, бик бетеренгән бер хатын иде. Ярты гомере больницада үтә иде бичара хатынның. Баштарак Римманы да бимазалап карадылар, массажын да, сихер-әкәмәтләрен дә күп ясады ул аңа. Зур кеше хатыны бит, әйтеп булмый — бу хатынның инде сүле суырылып, җаны чыгасы гына калган, дип. Шулхәтле бетсә дә бетәр икән кеше — барлык җире дә сәламәт кебек, барлык әгъзалары да исән, ә менә эченнән бөтен көче, хәле суырылып алынган. Әйтерсең лә кемдер аңа атланып канын эчкән, җегәрен суырган. Фабарисов белән якыннанрак танышкач, аннан бәреп торган кара көчне күргәч, Римма бу хатынның ни сәбәпле шушы хәлгә калуын аңлады. Бу хатынның тәне дә җаны да Фабарисов кулында иде, инде тормыш дәрте сүнгән, беткән бу хатын Фабарисовка кирәк тә түгел иде.

Ул аны күбрәк больницада тотты. Аңа аерым бүлмә билгеләнгән һәм Римма бу авыру хатын янында булырга тиеш иде. Фабарисов үзе больницага сирәк килә, килгәндә дә күбрәк вакытын Римма белән сөйләшеп уздыра. Әмма бу юлы Фабарисовтан аның милләтче күршеләре турында сүз башлавын көтмәгән иде Римма. Тегеләй уратып карый шымчы абзый, болай урата, әмма күпме уратса да, нәрсә әйтә алсын алар турында Римма? Ул алар белән йөрешми, очрашса да, ишек төбендә генә очраша, хәтта, алар туры килсә, бер лифтка да утырмый. Римманың алар турында артык нәрсә белмәвен Фабарисов үзе дә сизеп тора бит, нигә һаман кысталган мәче кебек аның тирәсендә бөтерелә соң ул? Фабарисов ул милләтчеләр турында Римманың үзенә караганда да күбрәк белә бит, әнә, иренең — Тимербулат, хатынының Мәрьямбану исемле икәнен дә белә хәтта, Римма аларын ничә ел янәшә яшәп тә белми иде. Нәрсә кирәк соң бу кешегә Риммадан, нәрсә дип сава, капшый ул аның күңелен?

— Нәрсә кирәк соң сезгә миннән, Хәррис абзый? — дип сорап куйды Римма, үзенә генә хас кызулык белән. — Ул милләтчеләрне күрмәс өчен мин өйгә дә төнлә генә кайтам, сез монда больницага килеп тагы шуларны искә төшереп утырасыз.

«Әйтергә микән бу хатынга, юкмы?» дигәндәй, Фабарисов озак кына Риммага сынап карап торды. Аннан, кискен бер карарга килеп, Риммага иелә төшеп, өздереп әйтеп куйды:

— Аларны күралмаучылар бер син генә түгел. Аларның зыяны бик күп кешеләргә тия... Без берләшеп кенә аларны җиңә алабыз.

Римма сәерсенеп китте. «Нигә кирәк аларны җиңәргә? Йөрерләр-йөрерләр дә туктарлар» дип уйлады ул. Ә нигә бу эшләр турында Фабарисов Риммага сөйләп утыра әле? Римма нәрсә эшли ала алар белән?

Римма бу соравын Фабарисовка да бирде.

— Аларны аерырга кирәк, — диде Фабарисов, инде читкә-чатка кереп тормыйча.

Римма, ялгыш ишетмәдемме дигәндәй, шаккатып аңа текәлде.

— Ә мин монда причем? — диде ул, бераз аңга килеп.

Фабарисовның аны ниндидер пычрак, шикле эшкә этеп кертергә маташканын ул инде аңлый башлаган иде.

— Безгә сезнең ярдәм кирәк, сеңелем, — диде Фабарисов, бу сихерче хатынны бераз өркеткәнен чамалап. — Монда син генә ярдәм итә аласың.

Инде Римманы да кызыксыну баскан иде. Фабарисовның үзе белән шулай ачылып сөйләшүе аңа бер яктан килеп кызык булса, икенче яктан, бу тәкәббер татарларга зыян салу фикере аңа ошап китте.

— Тукта әле, Хәррис абзый, ә нигә кирәк аларны аерырга? — дип сорады ул кызыксынуын баса алмыйча.

Фабарисов бу сихерче хатынны юк-бар белән генә ышандырып булмасын аңлады, чаршау читен бераз күтәрергә булды.

— Үзең күреп торасың, алар хәзер шәһәр өчен куркыныч көчкә әйләнеп баралар. Әле моның белән генә бетәрме? Казан урамнарында ничек котырыналар алар хәзер, бездә дә шул хәл килеп чыкканын көтәргәме? Аларның безгә проблема тудырганын көткәнче, үзләренә проблема тудырып торырга кирәк. Башлары чыкмасын шул мәшәкатьләрдән, үз кайгы-хәсрәтләреннән...

Римма аңлаган кебек тә булды, аңлап та бетермәде. Нәрсәнедер әйтеп бетерми иде Фабарисов. Һәм әйтмәячәк тә... Ә Римма нишләргә тиеш була соң бу гаилә белән? Бу Фабарисов та, чекист башы белән, шул сихер-михерләргә ышанамы икәнни? Шуның белән генә гаилә хәтле гаиләне җиңеп булыр дип уйлыймы? Римма бит күрә — алар гел бергә йөриләр, бер-берләрен яратулары бөтен дөньяга кычкырып тора. Шулар арасына Римма керә аламы авыл карчыкларына гына яраган им-томнары белән?

— Барып чыкмас, Хәррис абзый, — диде ул кул селтәп. — Бу йортта аларны минем кебек куралмаган кеше юктыр, сез әйткәнне көтмәдем инде мин, өшкереп тә карадым, төкереп тә карадым, йөргән юлларына, сихерләп, тоз да, су да сиптем... Исләрендә дә юк, тагы да дәртләнеп, тагы да кочаклашып йөри башладылар. Булмас эш уйлап тапкансыз...

— Ә син алымнарыңны үзгәртеп кара... Хатын-кыз бит әле син... Ягъни бик чибәр хатын...

Римма, гәүдәсен артка ташлап, хихылдап көлеп җибәрде. Кайсы яктан килеп сыйпарга кирәген белә бу картлач! Әмма Тимербулатны күз алдына китерде дә хатын тагы куырылып килде. Гомерендә ир чырае күрмәсә дә, ул бандитка карамаячак Римма! Көчен дә, сүзен дә әрәм итмәячәк.

— Милләтчеләрегез үзегезгә булсын. — Римма, сүзне беткәнгә исәпләп, урыныннан кузгала башлады. Инде аңа бу турыда сөйләшү кызык түгел иде. Ул, тек-тек басып, чыгып китә башлады. Әмма Фабарисов башланган сүзне, эшне ярты юлда калдыра торган кеше идеме соң? Ярты юлда калдырасы булса, ул бу сүзне башлап та тормый иде. Теләсә ничек булсын, теләсә кем аша, әмма Фабарисов Мәрьямбану белән Тимербулатны аерачак иде. Нигә, ничек икәнен ул әле үзе дә ачыклап бетермәде, әмма ул инде нәтиҗәне күрә, бу эшнең ахырын күрә. Ә нәтиҗә бер — алар аерым. Мәрьямбану ялгыз. Мәрьямбану милли хәрәкәттән читләшкән. Мәрьямбану Фабарисовка якынайган... Ул аны үз максатларына файдаланыр — хатын-кыз буларак та, милләтче буларак та... Үзенә эшләтер... Үзенеке итәр...

Фабарисов инде ишеккә җиткән Римманы келәшчәдәй бармаклары белән эләктереп алды.

— Ә мин, сеңелем, бик җитди нәрсәләр турында сөйләшәм бит синең белән. Сүз бит синең, минем теләү-теләмәү турында гына бармый. Сүз дәүләт куркынычсызлыгы турында бара. Әллә сиңа башкача аңлатып караргамы? Әйтик, ничек итеп малаең өчен больницадан наркотиклар ташуыңны искә төшерергәме? Без бит барысын да беләбез...

Римма сискәнеп китте. Ул инде сүз беткән дип уйлаган иде. Әнә кайсы яктан китереп сукты аңа бу шымчы карт. Каян белә ул Вованың наркоман икәнен? Римманың аның өчен шыпырт кына больницадан көчле дарулар ташыганын каян белә? Моның күршеләргә нинди катнашы бар?

— Мин нишләргә тиеш? — дип сорады ул бик кыска гына, эшнең артык җитдилеген һәм куркынычлыгын сизеп.

— Анысы синең эш инде, сеңелкәем. Миңа нәтиҗәсе булсын, аңлыйсыңмы, нә-ти-җә-се!

Фабарисов чыгып киткәч тә, Римма бик озак аңга килә алмый торды. Нинди нәтиҗә? Риммада бу милләтчеләр кай-

гысымы?! Бердәнбер улы, ундүрт яшьлек Вовасы наркотиклар куллана башлаган. Моны белгәч, башта Римма улын буып үтерерлек булды, елады, янады, ялварды, әмма файдасы булмады. Малай көн саен урамнан миңгерәеп, күзләре тонып кайта башлады. Аннан өйдән әйберләр юкка чыгарга тотынды. Соңрак улының аяк-кулларын көзән җыерырга, бөтен гәүдәсе тартышырга кереште. Улының күз алдында үлеп баруын күреп, аның кан тамырларына көчле уколларны ана үзе сала башлады. Шул ук вакытта баласына карата сихер-гипнозларын, массажларын да туктатмады. Ак һәм кара көчләрдән, изге һәм явыз рухлардан елый-елый ярдәм сорады, бердәнбер улын бу афәттән коткаруларын ялварды... Әмма тәкъдир аның баласының бугазыннан ычкындырмаска эләктергән иде. Бу, бәлки, сихер һәм күрәзәчелек белән шөгыльләнгәне өчен аңа күкләрнең җәзасы һәм җавабы да булгандыр...

Римма күкләргә ялварган арада, җирдә аның каршына адәми шайтан үзе килеп басты. Адәми шайтан Римманы тагы да гөнаһлырак юлга төртеп кертеп җибәрде. Римма кеше гаиләсен җимерергә, Тимербулатны Мәрьямбанудан аерып алырга тиеш иде... Әмма ул вакытта Римма Тимербулатны үзе өчен аерып алуын белми иде әле. Ул моны Фабарисов әйткәнгә эшлим дип уйлады, әмма аның үз күңелендә дә бөгәрләнеп шайтан ята иде. Менә шул шайтан Римманы аздыра, аны Тимербулатка таба этә, котырта иде... Менә шул шайтанны юлдаш итеп, Римма тормышының икенче яртысын башлады. Гомеренең соңгы елларына, соңгы көннәренә керде...

* * *

Тимербулатның үзен кая куярга белми йөргән вакытлары иде... Кисәк кенә барысы да кирегә китә башлады. Кая анда дәүләт, кая анда бәйсезлек, кая анда демократия — хәтта бер оешманы да үзеңчә тоту мөмкин түгел иде. Завод-фабрикалар, зур-зур предприятиеләр ябыла башлады, ябылмаганнары эшләрен башкаларга тапшырырга мәҗбүр булдылар. Бер яктан аларны салымнар белән хөкүмәт буса, икенче яктан урам бандасы тынгы бирми иде. Хөкүмәтенә, урам бандаларына да түзәр идең, әмма мең төрле теркәлү, мең төрле кәгазь, мең төрле тикшерү белән теңкәгә тияләр. Хәзергә бары тик аракы сәүдәсе генә чәчәк ата, бу да вакытлы гына булырга охшаган, хөкүмәт бу төр эшмәкәрлекне дә үз кулына алырга җыена. Әгәр югарыда берәр таныш-белешең булмаса, шәхси предприятиең ничек бар — шулай юкка чыгачак. Тимербулатның анда танышлары күп-күбен, бу шәһәрдә ярты гомерен уздырган, әмма, милли хәрәкәткә йөреп, кү-

бесенә каты-каты әйтелгән, күбесе белән инде ара да бозылган. Әгәр Тимербулат алар каршына түш белән шуышып килсә, аңа да, бәлки, бераз йомшаклык күрсәтерләр иде, бу кечкенә генә мастерскоена эшләп китәргә ирек бирерләр иде. Юк, ир дә шуыша алмый, алар да Тимербулатка яшәргә ирек бирмиләр. Кем шулхәтле каныга Тимербулатка, кем атлаган саен аяк чала — ул үзе дә белми, әмма ай саен тикшерү, ай саен ябу белән янау... Инде салымнарны да түләп бетердем, тиешле кәгазьләрен дә җыеп тапшырдым, иркенәеп эшлим генә дигәндә, бер төнне бөтен төзелеш сарайларын ут төртеп яндырдылар. Тимербулатның гөрләп эшләп яткан предприятиесеннән кисәү башлары гына аунап калды. Барысы да бер төндә янды да бетте. Кем ут төрткән, бу кечкенә генә төзелеш мастерское кемгә комачау иткән — эзләүче дә, табучы да юк, һәм менә бүгенгесе көннән — Тимербулат эшсез.

Шушы төзелеш тирәсендә тамак туйдырып йөргән тагы дистәләгән кеше эшсез калды. Җитмәсә, Тимербулатның муеннан бурычы бар, бизнеста бит ул ярты эшеңне бурычка алып эшлисең, соңыннан түләү шартына килешәсең. Ахыры менә шушылай бетте эшнең... Тимербулат кая барып төртелергә дә белмәде, мондый авыр чакта берәүнең дә урамдагы бер милләтчегә, эшеңне яңадан башла, дип, акча биреп торасы килмәде. Күпләр аның артында: «Әнә, бәйсезлеге белән тамак туйдырсын инде», — дип көлделәр генә. Тимербулатның шартлап сынуын, туксанынчы еллар ыгы-зыгыларында бүлмәләрендә качып яткан шушы түрәләр каршында түш белән шуышуын, һич булмаса, кайгыдан эчә башлавын көттеләр... Тимер кебек бер милләтченең тәүбәгә килүен, үкенүен көттеләр. Янып күмергә әйләнгән төзелеш сарайлары, таралып беткән милли хәрәкәте белән Тимербулат берьялгызы торып калды...

Нәкъ шул чакта гаиләсендә дә аңлашылмаучылыклар башланды. Әллә Тимербулатның эшендәге шушы бәла-казалар тәэсир итте, әллә үзенең дә борчулары күп иде — Мәрьямбану соңгы вакытта күзгә күренеп үзгәрә башлады. Нур чәчеп торган йөзләре сабырланды, уйчанланды, тылсымлы күзләре түбән төште. Мәрьямбану аз сүзләнде, вакыты-вакыты белән бөтенләй сөйләшмәс булды. Башта Тимербулат моны Мәрьямбануның эшендәге хәлләр нәтиҗәсе дип уйлаган иде. Чөнки Мәрьямбануның да эшендә хәлләр кискенләшкәннән-кискенләшә бара иде. Мәрьямбануның педтехникумны татарчалаштырырга йөрүенә ярты коллектив каршы чыкты. Моны аңларга да була иде, чөнки татарча укыта башласаң, күпләргә эшләреннән китәргә туры килер иде, гомер буе урысча гына укыткан бу кешеләргә бүген генә татарчага күчү мөмкин түгел иде. Мәрьямбану моны үзе дә

бик яхшы аңлый иде, ул алга таба техникумда эшли алмаячак укытучыларга, шәһәр хакимияте белән берләктә, эш урыннары тапты, әмма берәүнең дә инде җайга салынган эшеннән китәсе килмәде. Кыскасы, бу укытучылар татарча өйрәнергә дә теләмәделәр, техникумнан да китәселәре килмәде аларның. Мондый чакта бер генә юл кала — директорның үзеннән котылырга. Һәм Мәрьямбануга каршы астан гына хәрәкәт башланды. Бу астыртын эш белән татарча белмәгән татарлар җитәкчелек итә иде. Аларга бөтен марҗа-урыс иярде.

Әмма Мәрьямбану хәтле Мәрьямбануны, бөтен республикага танылган галим-педагогны болай гына эшеннән җибәреп буламы соң? Җитмәсә, милли хәрәкәт тә аның ягында. Уйламыйча кагылып кына кара — хәзер урамга чыгып басарлар, ярты шәһәрне күтәрерләр. Техникумдагы күпчелек татарлар да Мәрьямбану яклы, алар хәзер монда үзләрен хуҗа итеп сизәләр, хәтта гомуми җыелышларны да татарча уздыра башладылар. Мәрьямбану — аларның лидеры, Мәрьям-аналары, ана арысланнары... Димәк, имза җыеп кына аны эштән куу мөмкин түгел. Димәк, башка сәбәпләр табарга кирәк, абынганын көтәргә, аз гына сөртенү белән, төртеп егарга, бөтен дөньяга каравыл кычкырырга кирәк... Һәм Мәрьямбануның дошманнары, шул мизгелне көтеп, тынып калдылар.

Һәм сәбәпне Мәрьямбану үзе бирде...

Техникумда күптән ислам тарихын укыту турында сүз бара иде. Әмма ул дәресләр программада каралмаганлыктан, башта факультатив, ягъни дәрестән тыш кына укытып карарга булдылар. Чөнки татар тарихы турында сөйләгәндә, ислам динен әйләнеп үтеп булмый, гомуми нигездә булса да, студентларга мәгълүмат бирергә кирәк. Әмма монда да проблема килеп чыкты — укытучылар юк иде. Дөньяви фәннәрне белүчеләр — динне белми, динне белүчеләр — дөньяви фәннәрдән хәбәрсез. Ә студент халкы ул — мәдрәсә карчыклары гына түгел, җәннәт бар, җәһәннәм бар, дип кенә аларны шаккатырып булмый, аларга барысын да фән аша аңлатырга кирәк. Алай да Мәрьямбану ислам тарихы укытучылары эзләп мәдрәсәгә барып карарга булды. Андагы тормышны күрү, укытучылары белән танышу Мәрьямбануның үзе өчен дә кызыклы иде, чөнки инде менә ничә ел шәһәрләрендә мәдрәсә эшләп ята, ә Мәрьямбануның да, милләтчеләрнең да анда барып караганы юк. Нинди дөнья икән ул, милләт язмышы турында алар ни уйлый икән, илдә барган бу кадәр гаделсезлеккә, әхлаксызлыкка ничек карыйлар икән, милләтне ничек саклап калырга уйлыйлар икән?

Әнә шундый уйлар белән Мәрьямбану шәһәр читендәге мәдрәсәгә юнәлде. Мәдрәсә элеккеге балалар бакчасына ур-

нашкан ике катлы таш бинадан гыйбарәт иде. Мәрьямбану, шәрык фильмнарыннан белгәнчә, затлы сарайлар, зиннәтле келәмнәр, чалма-чапанлы дин әһелләрен күрермен дип уйлаган иде. Бернинди бизәксез, чуар-чабырсыз, хәтта бераз фәкыйрь дә, кырыс залларны күреп, ул уңайсызланып куйды. Аларның техникумы бу дини уку йортына караганда мең тапкыр баерак, мең тапкыр купшырак иде. Ул, шәкертләрне эзләп, зур залга юнәлде. Шул чакта азан тавышы яңгырады. Мәрьямбануның чәч тамырларыннан алып аяк бармакларына кадәр яшен уты үтеп киткәндәй булды. Ул, әсәрләнеп, туктап калды, зал ишегенә сөялеп, намазга тезелгән балаларга текәлде. Аларның күбесе техникум студентлары яшендә иде, әмма Мәрьямбануның укучылары белән бу шәкертләр арасында җир белән күк аермасы иде. Мәрьямбану аларның кырыслыгыннан һәм артык җитдилегеннән курыкты, яшьлекләренә, хәтта балалыкларына да карамастан, дингә шулхәтле нык бирелүләренә һәм инануларына гаҗәпләнде. Бу яшьләрдә бер буш сүз, буш гамәл юклыгы күренеп тора иде. Мәрьямбану күреп өйрәнгән яшьләр белән чагыштырганда, болар бөтенләй башка дөнья, башка җиһан кешеләре иде...

Яшьләр намаз укып бетерделәр. Мәрьямбануны, олылап, түргә чакырдылар. Ул сүзне ничек башларга да белмәде, нәрсә сөйләсә дә, буш, кирәксез сүз булып чыгар кебек тоелды. Мәрьямбану шушы кыска гына вакыт эчендә шуны аңлап өлгерде — чын дин кешеләре белән бары тик иң кирәклесен, иң әһәмиятле дип тапканын гына сөйләшергә кирәк иде. Һәм ул шулай итте дә — үзенең йомышын әйтте, техникум өчен ислам тарихы укытучылары эзләп килүен сөйләп бирде. Яшьләр бераз җанланып киттеләр, әмма өлкәннәрдән узып бер сүз дә әйтмәделәр. Җавапны мәдрәсә ректоры үзе бирде:

— Безнең укыту сезнекеннән шактый аерыла бит, — диде ул. — Без, бөтен дөньяны Аллаһы Тәгалә барлыкка китергән, дибез, сез, үзеннән-үзе барлыкка килгән, дип өйрәтәсез. Без, кешелекнең башы Аллаһы кодрәте белән, Адәм галәйһиссәламнән башланган, дибез, сез, кеше маймылдан килеп чыккан, дип укытасыз. Бер бала башына без хәзер сезнең белән ике төрле тәгълимат тутырачакбыз һәм сезнең дәреслекләрнең, сезнең өйрәтүләрнең ялгыш булуын да әйтергә мәҗбүр булачакбыз. Әгәр сез шушыңа риза икән, без сезгә укытучылар бирәчәкбез.

Мәрьямбану сүзсез калды. Дин тарихы укытуны ул бөтенләй башкача күз алдына китергән иде. Әйтик, ислам диненең килеп чыгышы, Мөхәммәт пәйгамбәр турында, татарларның ничек итеп бу динне кабул итүләре хакында. Телевизордан гел шулар турында гына сөйлиләр бит. Инде бик үк диннең эченә кереп китәргә телиләр икән, бер-ике дога

белән намаз тәртибен өйрәтәләр, еллар буе гарәп хәрефләре ятлыйлар. Мәрьямбану өчен дин — менә шушылар иде. Ә монда — дөньяның килеп чыгышы, кешелекнең барлыкка килүе, галимнәр генә әйтә алырлык бөек тәгълиматлар... Мәрьямбану түзмәде, сорап карарга булды:

— Сез боларны нинди галимнәргә, нинди китапларга таянып исбатлыйсыз соң?

— Без сөйләгәннәр — кеше сүзе түгел, без сөйләгәннәр — Аллаһы Тәгалә сүзләре. Болар барысы да Коръәндә язылган, без бары тик шуңа таянып кына сөйлибез, шуннан чыгып барысын да исбатлыйбыз.

Мәрьямбану шактый уңайсыз хәлдә калды, биргән соравының урынсыз икәнен аңлады. Ә менә укытучылар белән нишләргә, ул бит монда мөгаллимнәр эзләп килде. Бәлки, милләт, тел мәсьәләсендә аларның фикерләре уртактыр, бәлки, шул юнәлештә алга таба бергә эшли алырлар? Мәрьямбану бу кешеләрдә зур гыйлем барлыгын, бу гыйлемне милләт балаларын тәрбияләүгә дә файдаланырга кирәклеген күңеле белән сизенә иде.

— Без — галимнәр, әмма әхлаксызлыкны җиңә алмыйбыз, — диде ул. — Дин безгә шуның өчен дә кирәк. Милләт өстенә эчкечелек кенә түгел, наркомания, СПИД үләтләре килә. Безнең шәһәр шуларның барысы буенча да беренче урында тора. Шуларга каршы динне ничек файдаланырга булыр икән?

Залдагылар дәшмәде. Мәрьямбану үзенең тагы урынсыз сүз әйтүен аңлады. Ректор тагы аңа ярдәмгә ашыкты:

— Бөтен хикмәт шунда, — диде ул, — дин бит ул вакытлы гына файдалана торган нәрсә түгел. Ягъни, авырлык килгәндә динне файдаланып, авырлык үткәч динне оныту — ул шул ук динсезлек инде, үз-үзеңне алдарга кирәкми. Без кешеләрне туганнан алып үлгәнчегә кадәр ислам кысаларында яшәргә өйрәтергә тиешбез, бу безнең бурычыбыз. Ислам дине яшәү рәвешенә әйләнгәндә генә, кешенең тормышында тәртип, бәхет, бәрәкәт булачак. Бу — Аллаһы Тәгаләнең вәгъдәсе. Милләт белән дә шулай ук. Бар татар халкы Коръән буенча яши башлый икән, сез әйткән бәла-казалар, бәхетсезлекләр аңа кагылмас, әгәр һаман үзенчә яшәп ята икән, шушылай булыр, шушылай бетәр. Тел дә коткармас, хәтта бәйсезлек тә коткармас. Әнә Россия бәйсез, телләренә дә бетү янамый, ә ел саен бер миллион кешеләре үлә. Бу милләт тә әхлаксызлыктан бетәчәк, имансызлыктан харап булачак...

— Безнең тел дип, дәүләт бәйсезлеге дип йөрүләребез ялгыш булып чыгамыни инде?

— Алары да кирәк. Әмма сез динсезләргә дәүләт бәйсезлеге алып биреп карадыгыз — нәтиҗәсе булдымы соң? Үзе-

безнең мөселман дәүләтен төзү өчен омтылырга кирәк. Тел дә кирәк, ул Аллаһы Тәгаләнең безгә биргән иң гүзәл нигъмәтләреннән берсе. Әмма дөньяның бу кадәр бозыклыгына телне генә каршы куеп булмый. Иман кирәк, барыбер иман кирәк, Аллаһы Тәгалә кушканча, дөрес яшәү кирәк. Ә дөрес яшәү үрнәге бары тик Коръәндә генә.

Мәрьямбануның бу мөселманнарга каршы әйтерлек бер генә сүзе дә юк иде. Аның каршы әйтәсе, бәхәсләшәсе дә килмәде. Аларның һәр әйткән сүзләреннән кырыс дөреслек бәреп тора иде. Бер якка да борыла алмыйсың. Тормышның бөтен барышы аларның хаклыгы турында кычкырып тора. Әмма бу хаклыкны күрүче, аңлаучы гына юк иде...

Мөселманча киенгән хатын-кызлар Мәрьямбануга мәдрәсәне күрсәтеп йөрделәр. Җыйнак кына уку заллары, пөхтә, тәртипле йокы бүлмәләре. Өстәлләрдә, стеналарда артык бернәрсә юк, эленсә дә, Коръән сүрәләре, мәчет-мәдрәсә сурәтләре генә эленгән. Өстәлләрдә дә дин китаплары һәм дәфтәр-каләмнәр генә. Монда барысы да бары тик гыйлем алу өчен генә көйләнгән, монда буш вакытны ничек уздырырга дигән проблема юк, ахры. Мәрьямбануны телсез-һушсыз иткәне, әлбәттә, китапханә булды. Идәннән алып түшәмгә кадәр киштәләргә калын-калын китаплар тезелгән, алар барысы да гарәп телендә. Болар Коръән тәфсирләре икән. Һәр сүрәгә, һәр аятькә том-том тасвирлама, аңлатма эшләнгән, алар, ниндидер могҗиза белән, ком чүлләреннән шушы кечкенә генә татар шәһәренә дә килеп эләккәннәр. Әмма монда аларны аңлаучылар бармы икән соң?

— Бездә гарәпләр укыта, — диде алар янына килеп туктаган ректор. — Өченче курска җиткәндә, шәкертләр дә гарәп телен үзләштереп бетерәләр, ягъни, менә бу китапларны укып, аңларлык һәм аңлатырлык хәлдә булалар.

— Коръәнне дә аңлыйлармы?

— Ул — беренче чиратта. Биредә төп таләп тә шул. Биредә укучылар Коръәнне үзләре дә аңлап, башкаларга да аңлатырлык булып чыгарга тиешләр.

— Һәм сез шуңа ирешәсез дәме?

— Әлхәмдүлилләһи, шәкертләребез өчен кызарырга туры килгәне юк. Без бер чыгарылыш эшләдек инде, аларның күбесе тирә-як авылларда, шәһәр мәчетләрендә имам булып торалар, укуларын чит илләрдә дәвам итүчеләр дә бар. Мулла булмыйча, дөньяви һөнәр сайлаганнары да динне ташламыйлар. Аллага шөкер, барысы да гел халык арасында, гел дин тарату юлында...

Шәһәр читендә, агач араларында күмелеп утырган мәдрәсә Мәрьямбануда бөтенләй башка бер галәмдә булып яткан тормышны хәтерләтте. Шәһәр бөтенләй башка тормыш

белән яши иде. Биредә төннәрен юл буйларына унөч яшьлек зиначы кызлар тезелеп баса, алар, бер телем икмәк, акча хакына үзләренең бала тәннәрен саталар иде, бу шәһәрдә СПИД үләте котыра, рәсми булмаган мәгълүматлар буенча, биредә хәзер илле меңнән артык шушы чирне йөртүчеләр бар икән! Бу бит тагы ун-унбиш елдан шәһәрдә шушы чир белән авырмаган бер генә яшь кеше дә калмый дигән сүз! Аларның күпчелеге — татарлар бит! Ата-аналары, эчеп, үз-үзләренә кул сала, балалары менә шушындый юлда, алга таба ни булыр бу милләт белән?! Ә без, тел, дибез, бәйсезлек, дибез, кемгә кирәк булыр соң ул черек гәүдәдәге тел, азгыннардан һәм җинаятьчеләрдән торган дәүләт?!

Мәрьямбануга үз улы өчен куркыныч булып китте. Ул хәзергә яхшы гына татар гимназиясендә укып йөри, әле ярый, анда бирергә башлары җитте. Ни дисәң дә, татар мәктәпләрендә җинаятьләр дә азрак, балалар да тәртиплерәк. Ә аннан соң — нәрсә? Кая барыр, кемнәр арасына килеп керер ул бала? Әнә әтисе — белеме, акылы була торып та, эшсез йөри, каян да башлап җибәрә алмый — бөтен җирдә каршылык. Яшь кеше бит мондый читләтүгә, кирәксезлеккә түзә алмый, ул эчүгә сабыша йә наркотикларга үрелә, йә, акча өчен, җинаятькә бара. Мәрьямбану Тимербулат өчен дә ут йотып тора әле, берәр башсызлык кына эшләп ташламаса ярар иде дип. Артык кызу канлы, артык горур, артык дөрес. Хәзер алай яшәп булмый шул. Ир кешегә — бигрәк тә.

Мәдрәсәдән кайткач, үзенең техникумына да Мәрьямбану бөтенләй башка күзләр белән карады. Барысы да бар кебек — еллар буе эшләнгән программалар, кат-кат тикшерелгән дәреслекләр, тәҗрибәле укытучылар коллективы. Башка уку йортларында да шушылай барысы да көйләнгән, тәртипкә салынган. Ә нәтиҗә — менә бүгенге тормыш. Шәһәр наркоманнар, эшсезләр белән тулган икән — бу бит алар укыткан, алар тәрбияләгән яшьләр дә шушы һәлакәт юлында дигән сүз. Менә бу мәктәпләр, техникумнар һәм халык тормышы икесе ике юлдан, икесе ике капма-каршы якка баралар кебек. Ике арада аерма, упкын тирәнәйгәннән-тирәнәя бара, хәзергә әле бу упкын үзенә корбаннарны халык арасыннан чүпли, әмма тиздән бу афәт бирегә дә үтеп керергә мөмкин бит?

Мәрьямбануның шомланулары урынсыз булмаган икән, беркөнне, шимбә дискотекасыннан соң, бәдрәфләрдә шприцлар таптылар. Бу инде биредә наркоманнар барлыгына туптуры хәбәр иде. Тулай тораkларны, кабинетларны, уку бүлмәләрен тентү, эзләнүләр китте. Һәм наркотиклар да таптылар. Бөтен милиция, хокук саклау органнары аякка басты. Шулай бит ул, белсәләр дә, наркоманнарга сүз әйтүче юк, ә

менә наркотиклар табылса, бөтен система хәрәкәткә килә. Техникумга хокук саклау органнарыннан, больницалардан, СПИД һәм наркомания үзәкләреннән килеп тулдылар. Кая анда татар теле, кая анда дин?! Һәр студентны, һәр укытучыны, рөхсәт сорап та тормастан, СПИДка тикшерә башладылар... Һәм биш студенттан шушы афәт табылды. Студентларның бишесе дә татар балалары иде...

Мәрьямбануның ул көннәрдә чәчләре агарып чыкты. Бу — бөтен техникум өчен генә түгел, бөтен шәһәр, милләт өчен дә зур фаҗига иде. Студентларның авылларда яшәгән ата-аналарын, туганнарын тикшерә, газаплый башладылар, алардан бөтен халык читләште, өрәктән качкан кебек качты, аралашмас булды. Студентлар җыелышы бу биш укучыны техникумнан куарга дигән карар чыгарды. Азгынлыкта бергә булсалар да, үлем юлында беркемнең дә алар белән бергә буласы килмәде.

Мәрьямбану техникумда дискотекаларны туктатты, туган көн мәҗлесләрендә, бәйрәмнәрдә аракы-шәраб кебек әйберләрне тыйды. Атна саен, көн саен булып торган күңел ачуларны, җыр-биюләрне дә кискен киметте. Техникум мәет чыккан йортка охшап калды. Әмма Мәрьямбану өчен бу мөһим түгел иде, ул коллективның бөтен көчен бары тик студентларга гыйлем бирүгә генә сарыф итәргә уйлады. Укытучылардан да, укучылардан да бары тик шуны гына таләп итте. Әмма техникумнан чирлеләр куылгач, наркоманнар бераз тыелып, посып калгач, ыгы-зыгы бераз басылгач, яшьләр дә, укытучылар да яңадан иске гадәтләрен куа башладылар. Аларга техникумның гөрләп торуы, дискотекалар, бәйрәмнәр, туган көннәр, тагы шуның кебек укуга бөтенләй катнашы булмаган чүп-чар кирәк иде. Аларга күңел ачарга кирәк иде. Техникумда кырыс тәртипләр кертергә теләгән Мәрьямбану белән күңел ачып яшәргә теләгән коллектив арасында каршылыклар, аңлашылмаучылыклар туа башлады. Әле кайчан гына Мәрьямбану өчен кыя кебек торган татар укытучылары да аны гаепли, аңламый башладылар. Урыс укытучылары исә Мәрьямбануны шушы СПИД хәлләреннән соң ук техникумнан кудырырга уйлаганнар иде, әмма никтер аны Казанда яклап чыктылар, кагылмадылар. Ул вакытта әле татар укытучылары да Мәрьямбану яклы иде. Хәзер исә хәлләр үзгәрде, Мәрьямбануга каршы урысы, татары, хәтта күңел ачулардан мәхрүм булган студентларга хәтле сүз әйтә башлады. Мәрьямбануның техникумда калу-калмау мәсьәләсе инде хәл ителгән дип әйтергә була иде. Аның соңгы тапкыр абынуын, күпчелек фикеренә каршы соңгы адым ясавын көттеләр... Һәм Мәрьямбану ул адымны ясады...

Беркөнне Мәрьямбану техникумга ап-актан киенгән мөселман кызларын алып килде һәм: «Болар факультатив рәвештә ислам тарихы укытачаклар», — диде. Кызларга башта бер кызыкка караган кебек карасалар да, соңыннан, аларның тарафдарлары арта баруын күреп, күпләр пошаманга төште. Бу мөселманнар милләт дип тә лаф ормадылар, бәйсезлек сүзен дә килде-киләксезгә кулланмадылар, әмма милләт фаҗигасенең дә, дәүләтсезлек фаҗигасенең дә төп сәбәбе имансызлыкта икәнен тиз арада күпләрнең аңына сеңдереп өлгерә алдылар. Коръәнне яттан белгән, милләт тарихын да күңелләрендә саклаган, саф татар телендә чыгышлар ясый торган намазлы, әдәпле, галим бу татар кызлары өс-башлары белән генә түгел, бөтен яктан да студент кызлардан аерылып торалар иде. Боларда җилбәзәклек, мәгънәсезлек, вакытны һәм сүзне бушка сарыф итү юк иде. Бу яшь кенә мөселман кызлары иң кирәген генә сөйлиләр, иң кирәген генә эшлиләр иде. Шул ук вакытта алардагы катгыйлык та таң калырлык иде. Аларны чәчәкле-чуклы киемнәр, бизәнү әйберләре белән дә шаккатырып булмый, алар егетләр ягына да күтәрелеп карамыйлар, гайбәт сөйләмиләр, бервакытта да кеше тикшермиләр иде. Мәрьямбану торып-торып гаҗәпкә калды — бөтен гомерләрен менә шундый әдәпле яшьләр тәрбияләүгә сарыф итәләр, ә нәтиҗәдә азган, бозылган бәндәләр белән дөнья тула. Менә шушындый мөселманнар кебек яшьләр тәрбияләү өчен аларга нишләргә соң? Нигә бу уку йортларыннан йә мескеннәр, йә наданнар, йә мещаннар гына чыга соң?

Башкалар белән бергә, бу сорауларга җавапны Мәрьямбану үзе дә эзләде. Мәдрәсә кызларының сүзләренә колак салгалый башлады, биргән китапларын алып укыды, дәресләренә кереп утырды. Һәм шул чакта Мәрьямбану ни өчен үзләре башлаган эшләрнең барып чыкмавын аңлады. Дәүләт бәйсезлеге өчен көрәшкәндә дә, милләт, милләт дип өзгәләнгәндә дә, кеше тәрбияләргә тырышканда да алар беркайчан да Аллаһы Тәгалә өйрәткәннәргә таянмаганнар бит... Һәркем үз акылына, үз көченә ышанып кына җиңәргә тырышкан... Һәм бер өлкәдә дә җиңеп чыга алмаган булып чыга түгелме соң? Алар Аллаһны әйләнеп үтеп кенә бәхетле булырга уйлаганнар, ә бәхет дип йөргән алдавычлары бик кыска гомерле булып чыккан, вакытлы рәхәтлек бетү белән бәхет тә беткән. Ә мәңгелек бәхет, мәңгелек иминлек бармы соң ул? Булса, аңа ничек ирешергә?

Кызларга ияреп, Мәрьямбану үзе дә намаз догаларына, намаз тәртибенә өйрәнә башлады. Мәрьямбану үзе дә гаҗәпкә калды — ул бөтен күңеле, җаны белән шушы саф дөньяга тартыла иде, ул кырыкка кадәр белмәгәннәрен йот-

лыгып укыды, моңа кадәр үзенең ни дәрәҗәдә сукыр булуын аңлап, уйга калды. Ул дөньяның бөтен төзелешендә Аллаһының хикмәтләрен күрде — ай һәм йолдызларның төзелешендә дә, җирдәге һәр бөҗәкнең һәм үләннең үз нәселен калдырып яшәп ятуында да Мәрьямбану бөек бер могҗиза күрде. Әмма иң хикмәтлесе — кеше иде. Кеше тәнендәге һәр күзәнәк Аллаһның барлыгына һәм берлегенә шаһәдәт биреп торалар иде. Кеше тәнендәге һәр күзәнәкнең Аллаһ Тәгалә тарафыннан билгеләнгән үз бурычы бар иде, кеше тәнендәге һәр әгъза, кырыс бер тәртип белән, бөек бер көчкә буйсынып, кешегә хезмәт итәләр иде. Кеше үзе тулы бер система, бер дөнья, җиһан иде. Кешенең әгъзалары гына түгел, аны чорнап алган дөнья да, хәтта фәрештәләр дә аңа хезмәт итү өчен көйләнгән иде! Аллаһы Тәгалә кешене бу дөньяның падишаһы итеп яраткан булган. Кеше, үз теләге белән, күктән чүпкә төшкән, алтын таҗын аракыга, азгынлыкка алыштырган икән…

Мәрьямбану, гаҗиз булып, тирә-ягына карады. Менә бу урам тулы исерекләр, ять-яшь наркоманнар, зиначылар, угрылар, җинаятьчеләр — алар да дөньяның патшасымы? Яки дөньяның патшасы, Аллаһның кадерлесе булып яратылып та, ялгыш юлга кереп китеп, харап булган кешеләрме? Беркем дә, мин ялгыш юлга керәм, дип, махсус адашу, бетү ягына китми бит, хак белән ялгыш арасында чик бик нечкә, кеше күңеле исә аннан да нечкә. Ул Аллаһы Тәгалә тарафыннан бәхеткә, иман белән яшәргә көйләнгән, тәртипле тормыш өчен программалаштырылган. Кан күзәнәкләренә мәңгелек бәхетнең сере, формуласы салынган. Аллаһ үзенең нурыннан кешенең җанына өлеш чыгарган, димәк, кешенең җанында Аллаһның нуры бар. Ул нурга сүнәргә, корым белән капланырга ирек бирергә ярамый. Шул нур белән бергә Аллаһның тәэсире, рәхмәте дә киселергә мөмкин…

Мәрьямбану үзе моңа кадәр язган дәреслекләрне укып чыкты һәм аңа куркыныч булып китте. Ул аларда дөнья хәтле хата тапты. Башкаларның дәреслекләре дә хатадан мыжгып тора иде. Имеш, Ай һәм Кояш, Җир һәм йолдызлар бернинди илаһи көчкә буйсынмыйча, үзләреннән-үзләре хәрәкәт итәләр икән, имеш, кеше маймылдан килеп чыккан, имеш, җирдә тереклек үзеннән-үзе барлыкка килгән. Һәм шуның ише куркыныч хаталар… Хакны белгәнче болай сөйләү әле кичерелергә дә мөмкин, әмма инде хакыйкатьне белгәч болай сөйләү — бик зур гөнаһ. «Димәк, безнең балалар каршына, студентлар алдына чыгып әйткән һәр сүзебез, һәр фикеребез — ялган? — дип үз-үзенә сорау бирде Мәрьямбану. — Димәк, дәреслекләргә, укыту рәвешенә дә үзгәреш кертергә кирәк? Сүзне иң беренче Дарвин нәрсә әйткән, Ци-

олковский нәрсә әйткән, дип түгел, бу мәсьәләдә Аллаһы Тәгалә нәрсә әйтә, дип башларга кирәктер? Әмма моның өчен аз булса да дини гыйлем кирәк, балалар каршына чыгып баскан укытучыларның үзләренең Коръән кушканча яшәүләре кирәк. Ә алар моңа әзерме соң?»

Алар моңа әзер түгел иде. Алай гына да түгел, алар моңа каршы иде. Чын мәгънәсендә динне тотарга, дин кушканча яшәргә иң беренче чиратта халык түгел, милли интеллигенция каршы иде. Чөнки бик күпләргә дөньяга карашларын да, яшәү рәвешләрен дә үзгәртергә туры киләчәк иде, сырлан кебек сарылган яман гадәтләреннән, күңел азгынлыкларыннан, җиңел, Алласыз тормыштан баш тартырга туры киләчәк иде. Аларның күбесе моңа әзер түгел иде. Аларның күбесе моны теләми иде.

Мәрьямбануның лекцияләрне һәм дәреслекләрне бераз үзгәртергә, дин кушканнарны да искә алырга дигән сүзләрен хәтта татар укытучылары да аңлап бетермәделәр һәм кабул итмәделәр. Имеш, алар дингә каршы түгел, әмма ул дин бары тик кешенең күңелендә генә булырга тиеш икән — татар укытучыларының төп дәлиле шул иде. Ә балаларга бу гыйлемне кем бирер — барысы да җилкәләрен генә җыердылар. Имеш, әнә мәдрәсәләр бар, имеш, әнә ата-аналар уйласын... Ә менә балаларга — синең каршыңда чын дөреслекне көтеп утырган яшьләргә кем ачар ул хакыйкатьне? Аллаһ сүзен әйтергә әзер түгелбез икән, ичмасам, ялган сөйләмик, кеше маймылдан килеп чыккан, бу дөнья үзеннән-үзе барлыкка килгән, үлгәч яшәү юк, дип әйтмик. Ул чагында ничек аңлатырга бу күренешләрне? Дөньяви дәреслекләр, нигездә, ялган сөйлиләр икән, Коръән буенча укытырга уку йортларыбыз әзер түгел икән, нәрсәгә таянып аңлатырга яшь кешегә бу дөньяны? Аны нәрсәләрдән сакланырга өйрәтергә? Аягына басмас борын харап булуыннан ничек саклап калырга?

Укытучылар, чыш-пыш килеп, Мәрьямбануга кырын карый башладылар. Әле моңа кадәр дәреслекләр дә ярый иде, татарча укыту өчен бергәләп күпме көрәштеләр, инде хәзер араларына дин килеп кереп, бер-берләрен бөтенләй аңламый башладылар. Кирәкми ул халыкка дин, халыкка акча кирәк, эш кирәк, концерт кирәк! Әгәр Мәрьямбануга дин бик кирәк икән — китсен әнә өенә, утырсын намазына, беркем тотмый, беркем тыймый. Ә техникумга ул динне кертә алмас! Урыслар гына түгел, хәтта моңа татар укытучылары да юл куймаячак! Аның артында шулай сөйли башлаганнар иде...

Мәрьямбануның сүзенә, киңәшләренә колак салучы булмады. Һәркем нәрсә белә, дәреслекләрдә нинди ялган язылган — шуны сөйли, шуны укыта иде. Бөтен дөнья шул ялган

белән бара, нигә әле алар гына мөгез чыгарырга, башларына бәла алырга тиешләр? Бер үк күренешләрне мәдрәсә укытучылары — Аллаһ кушканча, техникумныкылар дөнья кушканча аңлаттылар. Мәрьямбану шуларның уртасында торып калды. Ләкин укытучылар арасында үзенең тарафдарлары кимегәннән-кими барганын сизде ул. Ул арада техникумга тагы комиссия арты комиссия килә башлады. Мәрьямбануның татарча укытып ятуына күз йомыбрак караган Казан да аңа үзенең беренче кисәтүен ясады. Мәрьямбану өстеннән төрле җирләргә жалоба-шикаятьләр ява торды, астан гына аңа каршы имзалар җыя башладылар, кайберәүләр исә, ачыктан-ачык та Мәрьямбануга эшеннән китәргә тәкъдим ясадылар. Шушыларның барысын да оештырып йөрүчеләр — татар укытучылары, татар хатын-кызлары иде... Алар Мәрьямбанудан техникумда дин сабаклары укытуны туктатуын таләп иттеләр, чөнки мәдрәсә мөгаллимнәренең сөйләгәннәре аларныкына каршы килә, студентлар хәтта имтиханнарда да дөньяны дин белән бәйләп, дин белән аңлатып сөйли башлаганнар иде. Еллар буе язылган дәреслекләр, министрлыкларда расланган программалар, хәтта укытучыларның сүзләре дә кирәксез булып, аяк астында калды. Яшьләрнең бер өлеше, техникумдагы дәресләреннән тыш, мәдрәсәгә дин сабагы алырга да йөри башлады. Техникумда мөселманча киенгән кызлар, егетләр күренде. Татар яшьләре ислам дине өйрәтүләрен тынчу шәһәрдә саф һавага юлыккан кебек, йотлыгып сеңдерделәр, аларның күңелләре чистарып, йөзләре нурланып китте. Укучылар белән укытучылар арасында аерма, упкын барлыкка килә башлады. Бу аерманы тагы да тирәнәйтмәс өчен, йә укытучыларга да дингә килергә, йә укучыларга яңадан диннән китәргә кирәк иде. Хәзергә һәркем үз урынында калды. Барысы да соңгы сүзне Мәрьямбанудан көтте. Мәрьямбану дәшмәде. Ул уйчанланып, сабырланып калды, әйтерсең лә үз гомерендә иң мөһим сүзне әйтергә, иң кирәкле эшне эшләргә, иң хәлиткеч карарга килергә җыена иде...

Педагогия техникумында ниндидер ыгы-зыгылар бару турында хәбәр Фабарисовка да килеп ишетелгән иде инде. Тагы шул Мәрьямбану! Тагы шул милләтче хатын! Беркем белән киңәшмичә, техникумында дин дәресләре кертә башлаган диме? Шул гына җитмәгән иде шәһәргә! Инде бу милләтчеләр тынып калдылар, беттеләр дигәндә, хәзер болар дин белән китереп бәрергә җыеналар түгелме соң? Әле кайда диген — дәүләт уку йортында! Фабарисов Мәрьямбанудан барысын да көтте — техникумын гына түгел, бөтен шәһәрне татарчалаштырып бетерүен дә, җитәкчеләргә каршы митинг-пикет оештыруларын да, үзе кебекләрне ияртеп, хәтта хаки-

мияткә килү мөмкинлеген дә! Әмма Мәрьямбануның милләтне, милли хәрәкәтне дин ягына алып кереп китәргә тырышуын көтмәде Фабарисов. Һәм ул аны ашыгыч рәвештә үзенә чакыртты.

Чакыртуының башка, яшерен сәбәбе дә бар иде. Күпме генә онытырга тырышса да, сурәтен хәтереннән чыгарып ташларга азапланса да, оныта алмады Мәрьямбануны Хәррис. Түшәк өстендә ничә еллар үлем көтеп яткан хатынына карауга, ул бу урында Мәрьямбануны күрә иде. Аның янәшәсендә гел үткен, тере, дәртле һәм назлы Мәрьямбану була иде. Мәрьямбану Фабарисовның үтмәс чиренә әйләнде. Ул бу хакта аның үзенә сиздермәде, әмма, могҗиза көткәндәй, гел бер җай чыгуын көтте. Мәрьямбануның ирсез ялгыз калуын, Фабарисов ярдәменә мохтаҗ булуын теләде. Үзендә һәм анда булган талант, мөмкинлекләр белән, бу шәһәрнең генә түгел, дөньяның патшасы итәр иде аны Фабарисов, әгәр Мәрьямбану аныкы булса!

Әмма Мәрьямбану Фабарисовны күрмәде. Бер үк җыелышларда янәшә утырганда да, капма-каршы басып сөйләшеп торганда да Мәрьямбану Фабарисовны күрмәде. Хәтта көлеп тә, хәтта төрттереп тә, хәтта ачуланып та бернинди хиссиятен сиздермәде. Әйтерсең лә ул хатын-кыз түгел, салкын мәрмәр таш иде! Ә аның таш түгеллеген бик яхшы белә бит Фабарисов. Юкка гына күзәтми бит ул аны. Ул аның һәр адымын тикшертте, һәр әйткән сүзен яздырып барды. Хәтта өендә ире белән генә сөйләшкән сүзләр дә саклана Фабарисовның өстәл астындагы тасмаларда. Әгәр ул иркәләү, назлау сүзләрен Хәрриска әйтсәләр, аны шушы хатын кебек чиксез мәхәббәт белән яратсалар, Фабарисовка бу эше дә, дан-дәрәҗәләре дә, хәтта гомер буе җыйган байлыгы да кирәк булмас иде. Фабарисов исәп-хисап белән өйләнде, хатынын, аның ата-аналарын үсү, карьера өчен файдаланды, гомер буе яратуның нәрсә икәнен белмәде, хәтта бала чырае да күрмәде. Менә хәзер ничә еллар инде үлә алмыйча яткан хатынын саклап утырырга мәҗбүр Фабарисов. Тәнендә көч-куәте, җанында сүнмәгән дәрте, күңелендә яраткан хатын-кызның сурәте була торып...

Һәм Фабарисов могҗиза көтеп ятмаска, эшне ашыктырырга булды. Ул берьюлы берничә юнәлештә эшләде — Риммага Тимербулатны аерып алырга кушты, авыру хатынына теге дөньяга тизләтә торган дарулар бирә башлады, менә бүген Мәрьямбануны үз янына чакыртты. Тимербулатның мастерское да Фабарисов күз алдында көлгә әйләнде, кан белән костырачак әле Хәррис аңа теге вакытта әйткән сүзләрен. Мәрьямбануның техникумына да тикшерү арты тикшерүне Фабарисов җибәреп тора, бәлки, Мәрьямбануны шулар бе-

лән өркетеп, кулга төшереп булыр? Иң мөһиме — аны аз булса да үзенә якынайтырга, ияләндерергә кирәк иде.

Мәрьямбануны Фабарисов эчке бер тетрәнү, борчылу белән көтте. Әйтерсең лә үсмер егет беренче тапкыр сөйгән кешесе белән очрашу көтә! Инде алтмыш яше тулып килгәндә, ул бу чиреннән котыла алмасын аңлады. Котылырга теләмәде дә. Аның башында әллә нинди планнар, күңелендә әллә нинди шашкын хыяллар котыра иде. Гомер буе бала дип яшәде, әмма тезләренә утыртып бала сөя алмады. Фабарисов моны хатыныннан күрде, балалары булмасын белгән көннән ул аны кага-җәберли башлады. Шундый урыннарда эшләгәч, ул хатын аерып йөри алмый иде, Фабарисов өчен иң яхшысы — хатынының кисәк кенә үлеп китүе иде. Әмма хатын да бик сизгер булып чыкты — Фабарисовның һәр адымын, һәр хәрәкәтен, һәр эшен мәче кебек күзәтте. Фабарисов аның ризыгына нәрсәләр генә кушып ашатмады, эчкән суларына нәрсәләр генә салып карамады, әмма хәлле авыл кешеләренең бердәнбер балалары бу тормышка теше-тырнаклары белән ябышкан иде. Фабарисовның бөтен гомере үз хатынының үлемен көтеп узды. Һәм менә хатыны ничә еллар ни үлә алмый, ни терелеп китми, урын өстендә үләксә булып ята. Теге вакытта эчергән даруларның, агуларның нәтиҗәседер, аңы да юк, акылы да беткән, бөтен нәрсәсе астында. Шул ук вакытта табиблар кайсы төше авыртканын да әйтә алмыйлар. Менә ничә еллар инде Фабарисов шушы авыру хатыны белән газаплана. Аны больницаларга да Фабарисовның эш урыныннан куркып кына алалар. Алга таба алмый да башласалар, нишләр аның белән Фабарисов? Әле ул хатынның үләргә исәбе юк бит, әйтерсең лә ул үзе шыпырт кына иренең үлгәнен көтеп ята...

Гомер буе кешеләр язмышы белән уйнаган, теләсә кемнең язмышын, тормышын үзенчә бора алган Фабарисов белән бүген тәкъдир үз уенын уйный иде. Ул аның каршына гомерлек хыялы булган хатын-кызны чыгарып бастырды. Фабарисов бу хатынны җиңәргә, сындырырга көче җитмәвен аңлады. Аның каршында ул бөтенләй тәбәнәкләнеп, көчсезләнеп, мескен булып калды. Шушы бер хатын каршында Фабарисов көчсез, чарасыз иде.

Мәрьямбану бүлмәгә ак сын кебек килеп керде. Өстенә ак плащын кигән, башында ак берет, кара чәчләре, анда ябылып ятарга теләмәгәндәй, дулкын-дулкын булып җилкәләрен кочып алган. Мәрьямбануның озынча мәрмәр йөзе тагы да агарып киткән. Фабарисов ашыгып аның каршына килде, тигез урында сөртенеп китте. Мәрьямбануга өстен салырга тәкъдим итте, әмма ул плащын салмады, тын гына Фабарисов күрсәткән урынга килеп утырды. Фабарисов сүзне нәр-

сәдән башларга белмәде, озак итеп, күзләрен ала алмый Мәрьямбануга карап торды. Мәрьямбану да дәшмәде.

— Техникумнан жалобалар бар, Мәрьям ханым. — Фабарисов инде үзен кулга алган иде.

Уйнарга тек уйнарга. Кирәк икән, куркытып, кирәк икән, кытыклап та карарга. Кайсына кабар бу чибәркәй. Әмма барыбер кабар. Әле Фабарисов салган кармакка эләкмичә калганнары юк иде.

Әмма Мәрьямбану үзен бик җитди тотты.

— Ул мәсьәләне хәл иткән идек бит инде, — диде. — Кайбер фәннәрне татарча укытырга безгә министрлык үзе рөхсәт итте. Бу эшне хәзер жалобалар язып кына туктатып булмый.

— Сүз, Мәрьям ханым, татарча укыту турында бармый, әлбәттә, ул мәсьәләдә дә арттырып җибәрергә, мөгез чыгарырга ярамый, шуңа күрә без бу эшне дә күзәтү астында тотарга мәҗбүрбез. — Фабарисов бу очракта да үзенең кем икәнен искә төшереп, төрттереп үтте. — Сүз дин укыту турында бара. Сез бит ярты мәдрәсәне техникумга күчереп бетергәнсез, студентларга Коръән укыта башлагансыз, бу хакта татар укытучылары зарланып яза!

Моның арттыру икәнен Фабарисов үзе дә белде, тик аның Мәрьямбануны бәхәскә, акланугa тартып кертәсе килде. Аның «Бу эшне шушында гына калдырыйк» дип ялынуын көтте. Әмма Мәрьямбану акланырга да, ялынырга да ашыкмады.

— Сез техникумга барып үзегез тикшерә аласыз, — диде ул һәм торырга, китәргә җыена башлады.

Фабарисов сүзнең мондый борылыш алуын бөтенләй көтмәгән иде. Ул, кабаланып, Мәрьямбануның кулларына килеп тотынуын сизми дә калды.

— Китмәгез әле, Мәрьямбану ханым, — диде ул, тәне калтыравын ничек тә бастырырга тырышып. — Китмәгез әле... Минем сезгә әйтер сүзем бар...

— Эш буенча булса, эшкә килегез, Хәррис әфәнде. Сезгә язганнарның кайсы хак, кайсы ялган икәнен үзегез күрерсез.

— Эш буенча түгел... — Фабарисов каушый, бутала башлады. Менә ничек шулай, тота-каба, ир хатынына хисләреңне аңлатасың инде? Алтмышка җиткәндә, шушындый мәртәбәле урында эшли торып! Фабарисовның пеләшенә тикле тирләп чыкты. — Минем сезнең белән тормыш турында сөйләшәсем килә иде... Ирегезнең мастерское янып киткән икән...

«Яндырдыгыз!» дип әйтәсе килде Мәрьямбануның, әмма тыелып калды.

— Бер җиргә эшкә дә урнаша алмый икән...

Мәрьямбану әле һаман Фабарисовның тел төбен аңлый алмый иде. Нигә аның гаилә эшләренә катнаша соң әле бу кеше? Тимербулат теге вакытта аның белән бик сак булырга кушкан иде, аның шәһәрдә исеме дә Геббельс Фабарисов икән, ягъни провокаторларның, хыянәтчеләрнең атасы, атаманы...

Мәрьямбануның күзләренә кереп бетәрдәй булып, кулларына ябышып, нәрсә дип бөтерелә ул аның тирәсендә?

— ...Соңгы вакытта үзара да тыныша алмыйсыз икән... Берегез дин, ди, берегез мин, ди...

Фабарисов артыгын әйтеп ташлаганын аңлады, әмма соң иде инде. Мәрьямбануның күзләрендә ут кабынды, вулкан ата башлады, Фабарисовның аяк астында әйтерсең лә җир тетри иде...

— Ә сез каян беләсез безнең ни сөйләшкәнне?! — Мәрьямбану яңадан элеккеге Мәрьямбануга әйләнгән, ана арыслан кебек, Фабарисов өстенә килә иде. — Сез нәрсә?! Безнең юрган астында ни сөйләшкәнне дә тыңлыйсызмыни инде?! Шул турыда җирәнмичә әйтеп торасыз тагы!

Инде Фабарисов куркуга төште. Бу хатынны ничек тә тынычландырырга кирәк иде, югыйсә ул хәзер бу хәбәрне бөтен шәһәргә таратырга, бөтен шәһәрне Фабарисовка каршы күтәрергә мөмкин. Һәм Фабарисов барысын да бер селтәнүдә өзәргә булды. Болай итеп, Фабарисов берьюлы ике куянны атачак — органнар өстеннән дә шикне ала, үзенең хисләрен белдерергә дә форсат таба. Мондый җайлы вакыт башкача булмаячак, авызыңны ачкансың икән, сүзне үз файдаңа бетерергә кирәк иде.

— Монда КГБның катнашы юк, — диде ул, рәнҗегән бер кыяфәт алып. — Мин үзем сезгә битараф түгел. Шуңа күзәттем, шуңа тыңладым, шуңа күрә сезнең белән очрашу эзләдем...

Чәче коелып беткән бу карт шымчының үпкәләгән малай кебек кылануы, әллә нинди тозсыз, мәгънәсез сүзләр сөйләп торуы Мәрьямбануны хурландырды, оялтты. Ул инде үзенең бирегә ник килгәненә үкенә башлады, дин буенча да бит хатын-кыз чит ир-ат белән ялгыз калырга тиеш түгел, өченчегә юлдаш шайтан булыр диелгән. Ә монда бу бәндә үзе шайтан кебек боргалана, Мәрьямбануның күңеленә, җанына юл эзли. Мәрьямбануның тәне өшеп киткән кебек булды. Ул, Фабарисовның сүзләрен ишетмәгәнгә, аңламаганга салышып, чыгарга ашыкты. Әмма Фабарисов аның кулларыннан келәшчә кебек электереп алган, ычкындырырга исәбе дә юк иде. Мәрьямбану моңа каршы соңгы сүзләрен әйтергә, соңгы дәлилен чыгарырга мәҗбүр булды.

— Мин сезнең кебек кеше сатып көн күрүчеләрдән җирәнәм, — диде ул, Фабарисовның йөзенә бәреп. — Дөньяда

берданбер ир-ат булып калган булсагыз да, мин сезгә карамас идем...

Мәрьямбануның бу рәхимсез сүзләре, бәясе Фабарисовның бөтен тәнен, җанын пешереп, өтеп алды. Ул, кырт борылып, бүлмәсенең икенче башына китте. Әйтерсең лә аның өстенә чиләге белән пычрак су сиптеләр һәм — кем диген? Кем каршында йөз суларын түгәргә җыенды ул, кемгә ачылырга уйлады? Аның турында менә ничек уйлыйлар икән...

Фабарисов башын күтәреп караганда, Мәрьямбану бүлмәдән чыгып киткән иде инде. Фабарисов баскан урынында озак хәрәкәтсез торды. Алдагы йөреш әле уйланмаган иде. Фабарисов әле үзенең соңгы сүзен әйтмәгән иде. Һәм, һичшиксез, әйтәчәк иде...

* * *

Корбан бәйрәме алдыннан Мәрьямбану төш күрде. Бу — кыямәт көне икән. Мәрьямбану каядыр йөгерә. Арттан бөтен дөнья янып, җимерелеп килә. Мәрьямбану тар сукмактан йөгерә икән... Бер ягында — текә кыя, икенче ягында — җәһәннәм чокыры... Өстә — күктә ай белән кояш бергә кушылган һәм күк эрегән бакыр төсенә кергән. Анда ишекләр барлыкка килгән... Бөтен дөнья гөрләп, гүләп яна... Каршыга, кулларын сузып, бер төркем кеше йөгереп килә. Мәрьямбану коты чыгып уйлый икән: «Бу тар сукмакта борылырга да урын юк, очрашкач, болар мине таптап китә икән инде», — дип... Әмма төркемнең аңа җиткән бере җәһәннәм чокырына тәгәрәп төшә бара икән... Мәрьямбану, бөтен көчен җыеп, алга йөгерә, анда аңа котылу булырга тиеш кебек... Үзе, өзгәләнеп, улым кайда соң минем, ирем кайда дип уйлый икән. Кинәт кенә ул Әхмәтнең тавышын ишетә, улы: «Ашык, әни, ашык, өлгерә күр», — дип ялвара икән... Мәрьямбану күзен күккә күтәреп карый һәм ачык ишектә улының йөзен күрә. Әмма улының бүгенге балачагы түгел, ул олыгаеп киткән, йөзен сакал-мыек баскан. Әллә куллары да бәйле инде?

— Улым, сиңа нәрсә булды?! — Мәрьямбану, җир-күкләрне яңгыратып, елап җибәрә.

— Мин шәһит киттем, әни, — ди икән улы. — Мин Җәннәттә синең өчен дога кылам... Син дә ашык, әни. Син әле әзер түгел, өлгерә күр... Соңгы сәгать җитә, өлгерә күр...

— Атаң кайда соң, улым, атаң юк бит! Мин ничек син чакырган җиргә үзем генә барыйм?!

— Әти монда керә алмас, әни... Син үзең турында уйла... Ишекләр ябыла, өлгерә күр...

— Мине синең янга кертерләрме соң, улым?

— Синең урының монда, әни. Әмма син әзер түгел әле... Зинһар, ашык, мин сине бик сагындым, әнием...

Ул арада өермә Мәрьямбануны эләктереп ала да җир белән күк арасында бөтерә башлый. Аста — утлы җәһәннәм чокыры, өстә — утлар атып торган күк, анда инде барлык ишекләр дә ябылган, бары тик бер урыннан гына яктылык сирпеп, үзенә чакырып тора икән... Мәрьямбану инде ут каплан җиргә дә төшә алмый, күктә калырга да аның көче-кодрәте җитми икән... Ул, җир белән күк арасында бәргәләнеп, һәр мизгелдә үзенә ут кабуын көтеп, берьялгызы ачыргаланып-ачыргаланып кычкыра, ярдәм сорап ялвара икән... Әмма җир һәм күкләр инде буш, Мәрьямбануның үлем ачысы белән кычкыруын, ярдәм сорап ялваруын инде ишетүче юк икән...

Мәрьямбануның тилмереп, инәлеп кычкыруына башта Тимербулат уянды, аннан күрше бүлмәдән Әхмәт йөгереп керде. Мәрьямбану һаман тыела алмыйча үкси, һаман ярдәм сорап ялвара иде. Аннан ул, беренче тапкыр күргәндәй, улы Әхмәткә текәлеп карап торды, кулларын сузып, аның йөзен капшап карады. Бу бала — шул төштәге сакал-мыеклы Әхмәт идеме соң? Ә Тимербулат кайда? Менә бит, ул да янында... Йа Хода, болар барысы да төш кенә икән бит. Әмма ниндидер хәвефле, хикмәтле төш... Ниндидер хәбәр, кисәтү, ашыктыру...

«Ашык, әни, ашык, өлгермәвең бар...» Колагында һаман шул тавыш... «Син әле әзер түгел... Ишекләр ябыла... Син әле әзер түгел...»

Мәрьямбану, утка пешкәндәй, сикереп торды, ашыгып, көзгедәге сурәтенә күз салды. Көзгедән аңа шактый арыган, борчулы, моңсу бер хатын карап тора иде. Хатынның кара шомырт чәчләре җилкәләренә таралып төшкән, чәчләре белән бергә уй-фикерләре дә тәмам таралып, чуалып киткән иде... Ул, таң алдыннан күргән төшеннән айный алмыйча, шушы борчу-хәвефләрен юып төшерергә теләгәндәй, баштанаяк юынып чыкты, озын кара чәчләрен тарап үрде, бераз тынычланып киткән кебек булды. Бүген Гает көне иде. Барысы да җыелып, мәчеткә киттеләр. Гаеткә килгән халык, мәчет эченә генә сыймыйча, ишегалдына, урам-тыкрыкларга да тулган. Мәрьямбануның күптән мондый хәл күргәне юк иде — әйтерсең лә бөтен шәһәр купкан, әйтерсең лә бу таңда бөтен татар намазга тезләнгән. Әти-әниләренә ияреп килгән сабый балаларны, үлем түшәгеннән дә кубарылып чыккан карт-карчыкларны күреп, Мәрьямбануның күзләренә яшь бәреп чыкты. Менә бит аның милләте нинди, инде бетте дигәндә дә, инде болар эчеп үлә дип, баш очларында мәет козгыннары

бөтерелгәндә дә, Аллаһ каршына килеп тезләнергә үзләрендә көч, иман тапканнар, аракыларын да ташлап, кайгы-хәсрәтләрен дә онытып, Гаеткә килгәннәр. Әнә алар, саф-саф булып тезелеп, авыр эштән яргаланып беткән кулларын күккә сузып, Аллаһтан ярдәм сорыйлар, Аллаһка ялваралар. Бу татарларның күпчелеге, бәлки, бер дога да белмидер, намаз да укымыйлардыр, бәлки, гаеттән кайткач, кичләрен тагы үзләренчә яши башларлар, нәфес колы булырлар, әмма бу мизгелләрдә алар бары тик Аллаһның гына коллары иде, бары тик Аның каршында гына тезләнгәннәр иде.

— Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр! Лә-ә илаһә иллаллаһу, Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр!

Бу мизгелләрдә татарларның ире-хатыны, яше-карты бары тик Аллаһны гына олылый, Аңа гына табына, Аннан гына өмет итә иде... Туган туфракларына басып тәкбир әйткән татарларның йөзләре сабыр, уйчан, моңлы иде. Мәчет өстенә аварга торган таш йортлар, таш йортлардагы таш йөзләр, татарларның бер Аллага табынуын куркып һәм нәфрәтләнеп күзәтәләр иде. Аларга бу татарларның эчеп ятулары, наркоман, фахишә булулары артыграк иде, чөнки андый татар болар өчен түгел, бары тик үзләре өчен генә куркыныч, үзләре өчен генә фаҗига иде. Ә айнып намазга баскан татардан бөтен кяфер дөньясы калтырап тора иде. Һәм аларны намазга бастырмас өчен барысы да эшләнә иде...

Мәрьямбану шушы Гаеттән соң башыннан яулыгын салмады. Ул аны мәңге салмаска бәйләвен аңлады. Аңа өлгерергә кирәк иде. Улы Әхмәт тә Гаеттән соң өйгә кайтмады, мәдрәсә шәкертләре белән мәчеткә кереп китте. Тимербулатның бу көннәрдә эше аркасында кәефе юк иде, аңа Гает тә тәэсир итмәде, ахрысы, Мәрьямбануның пешергән коймакларын да ашап тормыйча, каядыр чыгып китте. Мәрьямбануның күңелендә бүген иртән күргән төшенең хәвефе һәм Гает шатлыгы, иренең читләшеп йөрүе һәм үзенең җанында барган үзгәрешләр — барысы бергә кайный, үз рәвешен, үз юлын алып бара иде. Мәрьямбану бүген Гает вакытында, Аллаһы Тәгалә каршында сүз бирде. Бу — бик зур, бик җаваплы сүз иде. Мәрьямбану үзенең калган бөтен гомерен милләтен Аллаһ юлына чакыруга багышларга, шуңа хезмәт итәргә сүз бирде.

Милләтенең карап торып эчеп үлүен, юкка чыгуын Мәрьямбану теләми иде, үзенең бөтен акылын, тәҗрибәсен, гомерен ул милләтенә хак юлга килү өчен ярдәм итәргә ниятләде. Мәрьямбану нәрсә генә югалтса да, нинди генә сүзләр ишетсә дә, ул бу юлыннан чигенергә тиеш түгел иде. Ул бу юлга китмәскә дип килгән иде.

Икенче көнне, мөселманча киенеп, Мәрьямбану эшкә чы-

гып китте. Ул үткәннәргә капкаларын япты, күңел күгенең моңа кадәр бикле торган ишекләрен киң итеп ачты. Ул ишекләрдән бөтен дөньяга якты нур бөркелә иде. Мәрьямбануның үзенең дә бар дөньясы нурга төренгән кебек булды, ул бу дөньяда нәрсә өчен яшәгәнен аңлый башлады, аның күңел күзләре ачылды, дөньяга ул инде бөтенләй башка күзләр белән карый иде. Әмма дөньяга мондый Мәрьямбану кирәк идеме соң? Кемнәр көтеп тора иде бу ак яулыклы татар хатынын милләт тормышында? Ат кебек авыр эштән һәм күңел ачулардан торган татар тормышында кемнәргә таяныр, кемнәр тарафыннан кыйналыр бу ялгыз хатын — мөселман хатыны? Үз ире аңлармы? Тирә-юньдәгеләр аны тилегә генә чыгарып калдырырмы? Барысы тарафыннан да этелеп һәм төртелеп, моңа кадәр башкарган барлык хезмәтләре онытылып, тагы исерек милләтнең аяк асларында калырмы бу дини татар хатыны?

«Әйе, әйе, әйе» дигәндәй, таш йортның бөтен тәрәзәләреннән шашкын көй-җыр бәрә, кычкырган, талашкан, көлгән, елаган тавышлар ишетелә, урысы, татары, мукшысы бергә укмашып, күңел ача, сугыша, җан асрый, җанын сата иде...

* * *

Тимербулатның кичләрен йорт каршындагы кечкенә бакчада һава сулап утыра торган гадәте бар иде, бу юлы да Римма аны шунда күрде. Күршесе кечкенә генә бер эт баласы тоткан, көрәктәй зур куллары белән бу җан иясен сыйпап, иркәләп утыра иде. Фабарисов мәҗбүр иткәнгә генә түгел, беренче тапкыр Римма Тимербулатка кеше итеп, ир-ат итеп кызыксынып карап куйды. Бу зур, мәһабәт гәүдә ниндидер эчке сызланудан бөкрәеп килгән, сынып киткән кебек иде. Римма әле аның митингларда, йодрыкларын күккә чөя-чөя, җир тетрәтеп чыгыш ясаган вакытларын хәтерли. Әлек телевизордан һәр көнне аларны күрсәтәләр иде бит, халыкның шушы милләтчеләр белән тәмам котын алып бетергәннәр иде. Үтсә дүрт-биш ел вакыт үткәндер, барысы да тынып, басылып калды. Моны хәтта Римма да сизә. Хәзер митинглар да юк, кайнар бәхәсләр, сүз көрәше дә юк... Әллә тормыш басты кешеләрне, әллә үзләре бу мәгънәсез көрәштән туеп туктап калдылар. Риммага хәтта күңелсез булып китте. Әле ул милләтчеләр карак түрәләргә тынгы бирмиләр иде, хәзер дөрес сүзне әйтүче дә юк. Менә бу ир дә бүгенгесе көндә бөкшәеп, эт баласы кочаклап утырырга тиеш идеме инде? Таулар күчерерлек көч-кодрәте, яшьлеге, сәламәтлеге булганда? Әле җитмәсә, мастерскойларын да ут төртеп яндырганнар дип сөйлиләр, каккан казыклары да калмаган, ди.

Римма әкрен генә Тимербулат янына килеп утырды.

— Нәрсә, күрше, ял итәбезме?

Тимербулат, аптырап, янындагы чибәр хатынга күтәрелеп карады. Әйе, бу — күрше хатыны иде. Тимербулат аны элек тә күргәләде, әмма бу хатын, үзе башлап сәлам бирү түгел, биргән сәламне дә алмый иде. Хәтта Тимербулатлар утырган лифтка да утырмый иде ул. Нәрсә булган аңа, Тимербулатның хәлен белергә янына ук килеп утырды? Берәр нәрсә кирәктер дияр идең, нәрсәсе бар бүген Тимербулатның? Ни эше, ни дәрәҗәсе дигәндәй... Әмма шундый авыр, борчулы көннәрендә, бер тере җанның үзе белән сөйләшә башлавына, хәлен белүенә барыбер сөенде Тимербулат.

— Хәзер ял итәргә генә калды инде, күрше... Үзең беләсең, эшлим дисәң дә эшләтмиләр, яшим дисәң дә яшәтмиләр...

Алар шулай бик җиңел генә, бер-берләрен гомер буе белгән кешеләр кебек сөйләшеп киттеләр. Күрше хатынның исеме Римма икән, атасы ягыннан — керәшен татарларыннан. Татарчасы да бик яхшы. Авылда әбисеннән шулай өйрәнеп калган. Татар телен белгән, татарча сөйләшкән һәр кеше Тимербулат өчен туганы кебек якын иде. Ул кешеләрне диненә бүлеп карамый, аның дине — тел, таләп иткәне — тел, сокланганы — тел. Марҗа дип уйлап йөргән күрше хатынының шулхәтле матур итеп, килештереп татарча сөйләшеп утыруы Тимербулатны уятып җибәргән кебек булды. Яшисе килеп китте. Менә тел, тел, дип йөрүләре юкка булмаган бит, әле бу хатын берничә ел элек татарча сөйләшергә дә хурлангандыр, нәрсә әйтсәң дә, әнисе марҗа бит. Ә менә бүген Тимербулат кебек бер ата милләтче белән рәхәтләнеп татарча сөйләшеп утыра. Бу хатын Тимербулатның төзелеш мастерское янып китүен дә белә икән, газетадан укыган.

— Яңадан эш башлап җибәрергә уйлыйсызмы соң? — дип сорап куйды Римма сак кына, артык тирәнгә керүен сиздерәсе килмичә.

— Кая хәзер эш башлау! Беркем акча биреп тормый. Аракы сәүдәсенә алынасы килми, ул тиздән барыбер дәүләт кулына күчәчәк. Зур бизнеска зур түрәләр якын җибәрми — үзләренә кирәк... Нәрсәдән башларга да белгән юк инде. Бәлки, «КамАЗ»га барып карармын...

Әлбәттә, Римма өчен бу кешегә кредит алырга ярдәм итү дә, эш башлап җибәрергә булышу да берни тормый иде. Аның клиентлары арасында шәһәр башлыгыннан алып завод директорларына кадәр — барысы да бар. Үзенең күп танышлары өчен Римма шушы сеанслары вакытында сөйләшеп кала, барысын да шушы зур кешеләр аша хәл итә. Ярдәм сорап аның янына килгәннәр икән, алар да Риммага ярдәм итәр-

гә тиешләр. Һәм ярдәм итәләр дә, чөнки бу кешеләр өчен ниндидер кәгазьгә кул кую, кемнедер эшкә урнаштыру яки квартиралы итү — чүп тә түгел. Әлбәттә, Римма да өлешсез калмый, аның ярдәме белән эшкә урнашучылардан да, квартира алучылардан да ул үз өлешен ала, шуңа рәхәтләнеп яши. Менә хәзер бу күршесенә ярдәм итү аңа берни дә тормый ул торуын, Фабарисов кушканнарны үтәү өчен ярдәм итми дә булмый. Әмма ничек аны орды-бәрде генә әйтәсең? Имеш, күрше хатыны бер күреп сөйләште дә, ярдәм итәргә алынды... Алай булмый ул, шикләнүе бар, ә Римма бу кешедә шик уятырга тиеш түгел, киресенчә, ул аны үзенә якынайтырлык итеп хис уятырга тиеш. Фабарисов нәтиҗәне сораячак, ә нәтиҗә — Тимербулатның хатыныннан китүе, йә булмаса аралары бозылу... Монда инде зур абзыйларың гына ярдәм итә алмас. Нәрсәдән башларга соң? Ничек сүзне дәвам итәргә? Шулчак Римманың күзе Тимербулат кулындагы көчеккә төште. Менә бит сүзне дәвам итәргә сәбәп!

— Бигрәк матур эт баласы... Күрше булсак та, шундый матур этегез барын белми идем...

— Өйдә тормады ул. Мастерскойда яши иде. Янганда чыгып кача алган. Соңыннан чак таптык үзен куаклар арасыннан. Шулай бит, Сигнал?

Көчек иркәләнеп кенә чинап куйды. Римма да, батырчылык итеп, аның йомры башыннан сыйпап алды. Көчек колакларын тырпайтты, гәүдәсе җыерылып килде, үзе Тимербулатның тез араларына посты.

— Беркемне якын җибәрми, — диде Тимербулат, көчекне юатып. — Малай белән генә бик дуслар. Менә хәзер кая куясы булыр инде...

— Ничек инде — кая?

— Хатын өйдә эт асрауга каршы. Эт булган өйгә фәрештәләр керми, диме шунда... Ерунда, билгеле. Эт дип әйткәләшеп тә булмый.

Бу — Римманың көткәне иде. Иң мөһиме — сүз башланды, Тимербулат аңа гаилә серләренең бер читен күрсәтте. Менә бу эт сәбәпче булыр алга таба элемтәдә торырга, араларны өзмәскә. Бу гаиләгә үтеп керү өчен, бу әзмәвердәй ирне үзенә каратыр өчен мондый мөмкинлекне һич кенә дә кулдан ычкындырырга ярамый.

Римма үзе дә Фабарисов корган бу уенга тирәнрәк керә башлады. Чөнки бу ирдә Римманы үзенә тартып тора торган ниндидер кыргый көч-гайрәт, табигыйлек бар иде.

— Әгәр каршы килмәсәгез, бирегез миңа бу көчекне, — диде ул җылы, рәхимле тавыш белән. — Бездә торып торыр, ерак түгел, стена аша гына бит. Мастерскоегыз яңадан эшли башлагач, алырсыз. Шулай бит, Сигнал?

Сигнал, тын алырга да куркып, Тимербулатның тәненә сеңде. Аның ябык гәүдәсе дер-дер калтырый, сулышы Тимербулатның ботларын яндырып алыр төсле тоелды. Чү, тукта, бу бит эт баласының түгел, Тимербулатның тәне шулай дерелди, йөрәге чыгып китәрдәй булып дөберди түгелме соң? Тимербулатның башы әйләнеп киткән кебек булды. Тукта, нәрсә диде әле бу хатын, Сигнал бездә торып торсын, дидеме?

— Сез чынлап әйттегезме? Сигнал бездә торып торсын, дидегезме?

— Әйе, минем дә сезнеке кебек улым бар. Бергә уйнарлар. Кирәк чакта алып чыгарсыз, үзегез кереп йөрерсез... Шундый матур көчекне урамга чыгарып ташлап булмый бит инде, шулай бит, Сигнал?

Сигналның сулыш алганы да сизелми иде. Ул бу мизгелдә үзенең язмышы хәл ителгәнен, бер кулдан икенче кулга күчкәнен белеп, тоеп ята кебек иде. Әмма бу сөйләшүгә катнашып, үзенең фикерен дә әйтә алмый иде Сигнал. Әйтә алса, хуҗасына бу кара хатыннан ерак булырга кушар иде, аның янында һәрвакыт җеннәр өеренең йөрүен әйтер иде, бу хатынның тәненнән инде тирә-юньгә үлем нурланышы тарала башлавын кисәтер иде. Әмма Сигналның теле юк иде шул... Ул бары тик нәни көчек, эт баласы гына иде.

Шулай итеп, көчек Римма кулына күчте. Эт баласын тапшырганда, Тимербулатның куллары караңгыда ут кебек кайнар хатын-кыз кулларына тиеп китте. Әйтерсең лә аны ток тотты, яшен сукты. Римма да, утка пешкән кебек, кулларын тартып алды, көчек чак кына җиргә төшеп китмәде. Икесе дә уңайсызланып куйдылар. Дәшми генә подъездга керделәр, дәшми генә лифтта күтәрелделәр, ишек төбенә килеп җиткәч, инде ут яктысында, Римма Тимербулатка күтәрелеп карады. Йа Хода, әйтерсең лә аның каршында ерак яшьлегендә калган керәшен егете басып тора иде! Шул ук кара дулкын чәчләр, шундый ук үткен яшькелт күзләр, граниттан кырып ясалган кебек кырыс һәм матур йөз, түшәмгә тиеп торган имәндәй нык гәүдә... Һәм ничә еллар Римма янәшәсендә яшәп яткан шушы кешене күрмәгән, алай гына да түгел, дошман итеп йөргән, каргаган, бозарга тырышкан. Шул Фабарисов, карт чекист төртеп күрсәтмәсә, әле һаман Тимербулат яныннан карасына көеп, карганып үтеп йөрер иде. Фабарисов исенә төшүгә, Римма бик тиз бу дөньяга әйләнеп кайтты, тәвәккәлләп, соңгы сүзен әйтте:

— Эшегез мәсьәләсендә дә... Минем бер туганым банкта эшли, ул сезгә кредит белән ярдәм итә алыр иде. Әгәр теләсәгез, әлбәттә... Хәзер бер-береңә булышмасаң, яшәп булмый бит.

Тимербулат та җиргә төште. Әйе шул, бүген дә шушы

хәсрәт, иртәгә дә шушы борчу. Эш, акча, дөнья куу... Кемгә барып төртелергә, каян башларга? Бу тормышта батып, төпкә китмәс өчен, саламга да тотынырсың. Ә монда Тимербулатка таба салам түгел, ут кебек кайнар куллар сузылган. Тимербулат тагы кызарып китте, текәлеп Риммага карап торды, аннан, өздереп:

— Андый мөмкинлегегез булса, мин баш тартмас идем, — диде.

Иртәгә очрашырга килешеп аерылдылар. Сигнал, елыйелый, яңа кулга күчте. Тимербулат, башын иеп, гөнаһлы кешедәй, үз бусагасыннан атлады. Хәзергә әле һәрберсенең үз өе, үз тормышы иде...

* * *

Бүген Мәрьямбану эштән шактый соңга калып кайтты. Кайтты да, чишенмәгән дә килеш, йокы бүлмәсенә үтте. Аның бу мизгелләрдә беркем белән дә очрашасы, сөйләшәсе килми иде. Хәтта гомер иткән ире — Тимербулат белән дә... Соңгы вакытта Тимербулат белән ике арада салкынлык, пәрдә барлыкка килде кебек. Мастерское янганнан соң, Тимербулат бөтенләй икенче кешегә әйләнде — көннәр буе дәшми, уйланып йөри, дәшсә — усаллана, Мәрьямбану белән Әхмәткә дә каты-каты сүзләр әйтә. Мәрьямбану аңлый — ир кешенең шундый гайрәтле-көчле чагында эшсез калуы, кирәксезгә әйләнүе, бөтен җирдән дә тибәрелүе — бик авыр хәл. Әле мондый гаделсезлекне хатын-кыз буларак та күтәреп булмый, ә тормышны җигелеп тарткан ир-атка ничек түзәргә кирәк? Әмма Тимербулат Мәрьямбануга гел башка яктан килеп бәйләнә башлады — аңа Мәрьямбануның дин белән артык мавыгуы ошамый иде. Әйтерсең лә Тимербулатны алыштырдылар. Әйтерсең лә аның эченә җеннәр кереп утырды — ислам дине диюгә, күкерт кебек кабына Тимербулат. «Эчеңдә булса да, тышка чыгарма», — дип, ул Мәрьямбануны адым саен итәгеннән тартып, кисәтеп тора башлады. Ягъни Аллага ышансаң — ышан, анысы синең эш, әмма динне тормышка өстерәп кертмә — гаиләгә дә, эш урынына да дин тәртипләрен такма. Кешеләр моңа кадәр ничек яшәгәннәр, шулай яшәсеннәр, дин дип аларның башын катырма... Татарны хәзер җыр-моңнан да, күңел ачулардан да, аракыдан да аерып ала торган түгел... Аерырга кирәк тә түгел... Иң мөһиме — тел булсын, татарча булсын. Милләтне бары тик тел генә саклап калачак...

Тимербулат әнә шулай аңлата, телне, татарлыкны ислам диненә каршы куя иде. Татар өчен боларның икесе дә кирәклеген Мәрьямбану чит кешеләргә түгел, хәтта иренә дә

аңлата алмады. Милләтнең бөтен фаҗигасе, бәхетсезлеге имансызлыктан, динсезлектән икәнлеген ул хәтта татарларга да аңлата алмый иде! Исереклекнең чигенә килеп җиткән милләтне тел генә саклап кала алырмы? Милләт тәненә агуын җибәреп өлгергән әхлаксызлыкны, харамны, зина-үтерешләрне, эчкечелекне татарча сөйләшеп кенә бетереп булырмы? Бу тагы үз-үзеңне алдау, юату гына түгелме соң?

Бүген техникумда да татар укытучылары белән бик каты сөйләшү булды. Мәрьямбану бүген техникумга яулыктан килгән иде. Көне буе директорның яулыгын салып ташлавын, элеккечә шат, гүзәл, әшлекле Мәрьямбану ханым булып калуын көттеләр. Әмма Мәрьямбану яулыгын салмады. Гөрләп-кайнап торган уку йортында җитәкченең мәчет карчыклары кебек яулыкка чорналып йөрүенә хәтта татар укытучылары да гарьләнде, оялды. Бу — алар белгән, алар яраткан, алар лидер итеп тоткан Мәрьямбану түгел иде инде. Бу хатын аларга бөтенләй таныш түгел, чит-ят бер кеше иде. Өйлә вакытында Мәрьямбануның кабинетына бикләнеп намаз укуын да белгәч, татар укытучылары бөтенләй хафага төштеләр, урыслар белеп алганчы, Мәрьямбануның бу кыланышларын туктатырга, чик куярга кирәк иде. Алар, өйлә туры үтүгә, җыелышып Мәрьямбану янына керделәр.

— Мәрьям Гимрановна, — дип башлады сүзен бию укытучысы. — Безгә, әлбәттә, сезгә кисәтү ясау җиңел түгел, чөнки без сезне яратабыз, хөрмәт итәбез. Әмма әйтмичә дә булмый. Болай йөреп, сез коллективны үзегезгә каршы куясыз. Монда болай да ничә төркемгә бүленгән, үзегез беләсез...

— Ничек йөреп? — Мәрьямбану әле кайчан гына үзен яклап бөтен шәһәрне күтәргән татар укытучыларына карады. Укытучыларның кайсы башын түбән игән, кайсы бөтенләй читкә караган иде.

— Ну... Килешми сезгә бу яулык! Сез бит, в конце концов, мәчет карчыгы түгел. Урыс укытучылары гына түгел, студентлар да артыгыздан көлеп калалар. Өегездә теләсә ничек йөрегез, әмма техникумга болай килмәгез. Сез безне оятка калдырасыз бит...

— Барыгыз да шулай уйлыйсызмы?

Фикердәшләр, көрәштәшләр дәшмәде.

— Сезнең, ике сүзнең берендә, иманга кайтыйк, дип йөрүегез уен гына булдымыни?

— Һәрнәрсәнең урыны бар, — дип каршы төште карт татар теле укытучысы. — Педагогик коллектив берничек тә мәчет-мәдрәсә тәртипләре белән яши алмый. Үзегез беләсез — дин дәүләттән аерылган.

— Минем мөселманча киенүемнән дәүләткә зыян килә дип уйлыйсызмы?

— Безгә зыян килә, безгә! — Бу юлы инде бөтен укытучылар берьюлы шаулаша башладылар. — Эшкә зыян килә. Әнә анда урыс укытучылары тагы сезгә каршы имза җыя башлаганнар. Техникумда ислам фундаменталистлары тамыр җибәргән дип язалар, бу эшләрдә турыдан-туры сезне гаеплиләр. Болай яулык ябынып йөреп, сез үзегез үк раслыйсыз моның шулай икәнлеген. Сез бит безнең кебек гади укытучы гына түгел, җитәкче кеше! Без шулай йөрсәк, алар безне әллә кайчан эштән кудырырлар иде инде. Сезне кусалар, безгә дә чират җитәчәк...

Мәрьямбану бу укытучыларга Аллаһы Тәгаләнең хатын-кызга гаурәтен капларга әмер итүен әйтеп карады. Алар аны үзләре дә яхшы беләләр иде, югары белемле педагоглар, фән эшлеклеләре бит. Беләләр, әмма кабул итәргә теләмиләр. Башкаларга да дин кушканча яшәргә ирек бирмиләр, үз артларыннан өстериләр. Һәм Мәрьямбану гомер буе бергә эшләгән бу кешеләр белән ике арада кичеп чыга алмаслык тирән упкын күргән кебек булды. Алар бөтенләй бер-берләрен аңламыйлар иде. Дөньяга караш та, аны кабул итү, аңлау да бөтенләй капма-каршы. Мәрьямбану аларны дин тотарга мәҗбүр итми бит, анысы — аларның үз эше. Әмма алар Мәрьямбануны диннән чыгарга, башкалар кебек яшәргә өндиләр, мәҗбүр итәргә тырышалар. Һәр ике як та үзенең хаклы булуына нык ышанган, әмма Мәрьямбану ягында хөкемдар — Аллаһы Тәгалә, укытучылар ягында — кеше фикере. Мәрьямбану — ахирәт өчен, бу укытучылар дөньялык өчен генә тырышалар. Ничек шуларның икесен дә тигез итеп алып барырга? Диннән дә чыкмыйча, дөньялыкка да зыян китермичә? Бу сорауларга әле Мәрьямбануның үзенең дә җавабы юк иде. Әмма Мәрьямбану шуны яхшы белә — ул үлгәндә дә Аллаһының әмерләренә каршы барачак түгел, яулыгын да салачак түгел иде.

— Менә нәрсә, коллегалар, — диде Мәрьямбану, кисәк кенә арып китеп. — Мин, булдыра алганча, дин кушканча яшәргә тырышачакмын. Шушы килеш кабул итәсез икән — бергә эшләрбез, юк икән — аерылырбыз. Мин диннән китмәм, сездән китәрмен. Уйлагыз, сез — күпчелек.

Күпчелек уйлаша калды. Мәрьямбану техникумнан чыгып китте. Мәрьямбану бу сөйләшүдән шуны аңлады — бу татар укытучылары инде аны якламаячак иде. Аларны тел — берләштерә, дин аера иде... Һәм һәркем тәкъдирендә язылганны сайлап алырга тиеш иде...

Мәрьямбану үзенең өйдә дә, эштә дә ялгыз кала баруын сизде. Югыйсә ул элеккеге Мәрьямбану иде бит — милләтен өзелеп яраткан, аны кызганган, аңа ярдәм итәргә юлларын, чараларын эзләгән, бөтен акылын, тормыш тәҗрибәсен,

җанын шуңа багышлаган Мәрьямбану иде. Шул ук вакытта ул башка да иде — милләтнең котылу юлын ул бары тик ислам динендә күрде. Әмма милләт моңа әзер түгел иде. Кешеләр үзләрен һәлакәткә алып бара торган ияләнгән гадәтләреннән аерылырга теләмиләр иде. Һәм үзгәртергә тырышучыларга җавап та, караш та, мөнәсәбәт тә кискен һәм рәхимсез иде.

Мәрьямбану эшеннән китәргә булды. Техникумның шушы биналарын төзеп бетерүгә күпме көчен бирде, бөтен СССР буйлап берәмтекләп акыллы татарларны шушы коллективка туплады, үз куллары, үз акылы белән милли мәгариф системасын булдырды, дистәләгән дәреслекләр язды. Һәм шуларның барысын йөрәктән умырып алып ташлап, урамга чыгып китәргә кирәк. Чөнки бу коллективка, бу системага Коръәнчә яшәгән, дин тоткан Мәрьямбану кирәкми. Аларга байрак кирәк, аларга барысын җиңеп, ду китереп эш алып бара торган Мәрьямбану кирәк. Аның җаны, күңел дөньясы, иманы беркемне дә кызыксындырмый. Бу укылмаган намазлары, дөнья артыннан куып, ахирәт гамәлләрен онытканы өчен Аллаһы Тәгалә каршында нәрсә дип җавап бирер Мәрьямбану — монысы беркемне дә кызыксындырмый, борчымый иде. Мәрьямбану бу эшенең иманына зәгыйфьлек китергәнен сизенә башлады, чөнки аның каршына бүген укытучылар йә дин, йә без дигән мәсьәләне куйдылар. Мәрьямбану динне сайлап алды. Мәрьямбану эшеннән китәргә булды.

Әмма бу хакта ничек Тимербулатка әйтергә?! Соңгы вакытта ул болай да Мәрьямбану белән орды-бәрде сөйләшә, үзе дә эшсез, хәзер Мәрьямбану да эштән китәм дисә, ничек кабул итәр? Тагы тавыш чыгарырмы? Бу хәтле зур нәрсә турында әйтмичә дә булмый. Мәрьямбану үзе китми икән, аны барыбер җибәрәчәкләр, моны бүген Мәрьямбану яхшы аңлады инде.

Ул Тимербулатның йокы бүлмәсенә керүен, сүз башлавын көтте. Әмма Тимербулат кермәде. Аның янына, залга Мәрьямбану үзе чыкты. Каршында телевизор гөжләп эшләп торса да, Тимербулат аны карамый иде, карашы телевизор аша тәрәзәгә, тәрәзә аша әллә кайларга киткән иде...

— Мин эшемнән китәргә булдым, Тимербулат...

Тимербулат, беренче тапкыр күргәндәй, карчыга карашы белән Мәрьямбануга кадалды. Бу кыяфәтендә ул, чыннан да, Мәрьямбануны беренче тапкыр күрә иде. Мәрьямбану бөтен тәнен каплап торган озын күлмәк кигән, башына, чәчмуены күренмәслек итеп, ак яулык бөркәнгән. Битендә буяуның, иннек-кершәннең ник бер эзе булсын! Аның каршында элеккеге көләч, дәртле Мәрьямбану түгел, арыган, талчыккан мәчет карчыгы басып тора иде.

Тимербулат чәчрәп урыныннан сикереп торды.

— Син әллә эшеңә дә шушылай бардыңмы? Син үзеңнең кемгә охшап калганыңны беләсеңме соң?!

Инде Мәрьямбану гаҗәпләнде. Гомер иткән иренең мондый авыр мизгелләрдә нәкъ шул сүзләрне әйтүен көтмәгән иде ул.

— Әйе, Тимербулат, мин эшкә дә шулай бардым. Хатын-кыз шулай йөрергә тиеш тә.

— Соң син ике дипломлы хатын бит! Фән докторы! Мәчет карчыгы түгел. Дәүләт уку йортында директор! Ә син тиле хатын кебек киенеп йөри башлагансың!

Тимербулат бүген аеруча усал, аеруча зәһәр иде. Элек, милли хәрәкәткә йөргәндә, җитәкчеләрне шулай бугазларыннан ала иде ул, сүзе белән суя иде. Менә хәзер шушы бөтен зәһәрлек Мәрьямбану өстенә түгелә башлады.

— Хатын-кыз шулай йөрергә тиеш, Тимербулат. Минем болай киенүемнән беркемгә дә зыян юк бит.

— Ә үзеңә?! Иң зур зыянны син үзеңә ясадың хәзер. Сиңа хәзер беркем дә серьезно карамаячак. Син бит кеше арасында яшисең, аларның сүзенә дә колак салырга кирәк.

Мәрьямбану бу бәхәснең мәгънәсез бер эш икәнен белә иде. Тимербулатның исеме генә түгел, җисеме дә тимер күк, аны берничек тә үз фикереннән кире кайтарып булмый. Ә дин турында ишеткәч, бөтенләй котыра башлады ул хәзер. Бер караганда, юк кына нәрсә кебек хатын-кызның өс-башы. Әмма бүгенге заманда ул да бер билге, аерма шул — шайтан тамгасымы синең кыяфәтеңдә, Аллаһныкымы? Тимербулат, аның никахлы ире, Аллаһча йөрүгә каршы, ул Мәрьямбануны, үз теләге белән, шул азгынлык дөньясына, Фабарисовлар кочагына этәрә. Ул моны хәтта үзе дә аңлап бетерми, ахры, Мәрьямбануга бик күп ирләрнең күзе төшүенә ул гел көлеп кенә карады. Мәрьямбануның барысын да гашыйк итәрлек гүзәллегенә горурланды, бу байлыкның үзенеке генә булуына сөенеп, бәхет эчендә яшәде. Бәлки, аңа Фабарисов турында әйтергәдер, болай йөрүнең чит ирләрне аздыруга сәбәп булуын аңлатыргадыр?

— Болай киенү хатын-кызны чит ирләрнең азгын карашларыннан да саклый бит, Тимербулат, — диде ул соңгы саламга ябышкандай. — Үзең беләсең, бераз гына матур киенсәм, ир-аттан миңа тынгы юк бит. Барысының да үрелеп, тотып карыйсы килә. — Мәрьямбану һаман Фабарисов турында әйтә алмыйча газапланды.

— Кабергә кереп яткач, беркем дә тотып карый алмас, — дип кырт кисте Тимербулат. Аннан, арттырып җибәрүен аңлап, Мәрьямбануны иркәләп җайламакчы булды. — Салып ташла, әнисе, бу корамаларыңны, әнә мәчет карчыклары кисен-

нәр! Синең ул гарәп динең безнең шартларга бөтенләй туры килми, кешенең башын катырмагыз. Алай бик дин дип тилерәсең икән, әнә өйгә бикләрмен дә куярмын. Динчә булыр.

Тимербулат Мәрьямбануны шулай өйдә утырту белән куркытып карамакчы булды. Көне буе эштә чапкан, тормыш уртасында кайнаган Мәрьямбануның өйдә генә утыруын күз алдына да китерү мөмкин түгел иде. Ул хәтта ял көннәрендә дә эш табып чыгып йөгерә, милли хәрәкәтнең бер җыелышын калдырмый. Атна саен Казанына барып кайта, чакырулар белән чит илләргә дә чыгып китә. Һәм шушы, борча кебек Мәрьямбануны, яулык бөркәндереп, өйдә утыртырга мөмкинме? Таш яуса да мөмкин түгел! Тимербулат үз хатынын яхшы белә бит инде. Һәм Тимербулат тагы аның шушы сөяленә басып карамакчы булды.

— Әйе, әнисе, дин дип тилерәсең икән, өйдә утыртам мин сине. Бикләп куеп.

Әмма Мәрьямбану тыныч иде.

— Мин үзем дә эштән китәргә булдым, Тимербулат, — диде ул, җай чыкканга сөенеп. — Барыбер җибәрерләр иде, эшләр шуңа таба бара.

Тимербулатның башына китереп суккан кебек булды. Әллә бу Мәрьямбану, чыннан да, бераз җиңеләеп киткәнме? Мондый вакытта кем эш ташлый? Тимербулат үзе эшсез калды, шундый вакытта инде аңа булышасы, ярдәм итәсе урында — эштән китәргә?! Ә бу тормышны кем алып барыр?

Тимербулат шушы сорауларын Мәрьямбану өстенә ыргытты, бала башы кадәр йодрыкларын өстәлдә төя-төя, җавап таләп итте. Мәрьямбану дәшмәде. Сөйләшүнең мәгънәсе юклыгын аңлады ул. Үзенең, мөселман хатыны буларак, өйдә ирен, баласын тәрбияләп утырырга тиешлеген әйтергә теләде — әйтмәде. Тормышны ул — ир кеше алып барырга тиешлеген әйтәсе килде. Дәшмәде. Дин аркасында, кием аркасында ире белән шушындый зур низаг, аңлашылмаучылык килеп чыгар дип ул көтмәгән иде. Яшьтән яратышып өйләнешеп, унбиш ел гомерләрен чиксез мәхәббәт белән уздырган ир белән хатынның кинәт кенә аралары суынды да китте, алар бер-берләрен аңламый башладылар. Моның сәбәбен Мәрьямбану үзе дә белми иде. Юк, дин генә сәбәпче түгел монда. Тимербулат бит алай ук динсез кеше түгел, мәчетләр салырга күпме булышты, гел сәдакаларын биреп тора, гаетләргә йөри. Эш монда башкада. Милли хәрәкәт, бәйсезлек идеясе юкка чыккач, Тимербулат та үз-үзен югалтты, кинәт кенә яшәү мәгънәсен, максатын җуйды. Аның төп эше, төп омтылышы сәүдә түгел иде шул. Хәтта гаилә дә түгел иде, аның тормышында төп максат — милләт өчен көрәш иде. Көрәште дә Тимербулат, күпме татар мәктәпләре ачтыр-

ды, күпме мәчетләр салдырды, ул качак татарлар артыннан күпме йөрде. Аларны авыллар, шәһәрләр буйлап үзе урнаштырды, үзе таратты. Тимербулатның бөтен максаты — татар өчен яшәү иде, татарны яшәтү иде. Әмма Тимербулат бу хәтле зур эшләрне урамнан торып кына, милли хәрәкәт дәрәҗәсендә генә эшләп булмасын да белә иде. Шуңа күрә ул милләтнең акыл ияләрен туплап, сайлауларда җиңеп чыгу өчен бик нык көрәште, шулар белән бергәләп хакимияткә киләбез, милләт эшләрен парламентларда хәл итәбез дип хыялланды. Татар теленең һаман дәүләт теле булып китмәвенә дә йөрәге янды аның, җитәкчелектә иң надан, иң затсыз татарлар утыруга да хурланды, татар мәктәпләренең яңадан ябыла башлавын да ул үз фаҗигасе кебек кабул итте. Әмма халык сайлауларда бер генә милләтчене дә депутат итеп сайламады, урыслар аларны татар булганнары өчен куралмыйлар иде, татарлар алардан милләтче булганнары өчен курыктылар, җитәкчеләр сүзеннән чыкмадылар. Кыскасы, татар халкы үзе үк милләтчеләрне аяк астына салып таптады. Тимербулатны да татарлар дөбердәтеп шәһәр Советыннан да, Дәүләт Советыннан да төшереп калдырдылар, милләтчелек өчен берничә тапкыр тотып судка бирделәр, соңыннан мастерскоен да ут төртеп яндырдылар. Тимербулатның карап торган кыйбласы — милләт иде, менә шул милләт бүген үзе дә бетә, үзе белән бергә Тимербулат кебек ирләрне дә бетерә. Мәрьямбану да бу дөньяда япа-ялгыз, милләтче булганы өчен аны да чит итәләр, әмма аның хәзер сыенырга, ярдәм өмет итәргә Раббысы бар. Ә Тимербулат бит Мәрьямбанудан да ялгыз. Аның эчендә хәзер бушлык бит, дөм караңгы бушлык! Хәзер аңа Мәрьямбану да булышмаса, кем ярдәм кулын сузар, кем хак юлга чыгарга ярдәм итәр?

— Бу тормышны бергә-бергә алып барырбыз, Тимербулат. — Мәрьямбану, җан җылысы табарга теләгәндәй, иренә сыеныбрак утырды. — Әле, Аллага шөкер, йорт-җиребез бар, ризыгыбыз бар... Яшьлегебез, сәламәтлегебез бар. Бу тормыш болгана дип, без дә болганмыйк әле. Бары да җайланыр.

Гомер иткән хатынына әйткән сүзләре өчен Тимербулат инде үзе дә уңайсызлана башлаган иде. Әйтерсең лә эченә шайтан кереп утырган — Мәрьямбануның башындагы яулыгын, килеш-кыяфәтен күрүгә, әллә нәрсәсенә ярсып, җенләнеп китте Тимербулат. Йомшаклык белән аңлатып, болай йөрүен туктатырга иде дә бит... Ашыгыбрак әйтеп ташлады, ахры. Ул, көрәктәй куллары белән Мәрьямбануны үзенә ныграк кысты, иркәләгәндәй итте:

— Син, Мәрьямбану, эштән китәм дигән сүзеңне ташла. Анда синнән башка бетәләр бит алар. Уйлап кара, ул марҗаларың татарча укытуны шунда ук туктатачаклар.

— Анысын мин үзем дә аңлыйм. Эштән китәргә минем исемдә дә юк иде. Әмма бу кыяфәттә миңа техникумга юл ябык. Укытучылар мәсьәләне шулай куйдылар бит. Йә — эш, йә — дин. Башкача түгел.

— Ә син сал бу яулыгыңны... Менә шулай... Менә бит нинди гүзәллек, шуны яшереп йөрергә уйлыйсыңмы? Барысы да сокланып, кызыгып карасыннар сиңа! Мин көнләшмим. Синең минеке генә икәнеңне беләм бит мин.

Мәрьямбану читкәрәк тайпылды. Әйтерсең лә Тимербулат, тимер куллары белән эләктереп алып, аны тирән упкынга өстери иде. Ире белән кочаклашып бу упкынга очу рәхәт, ләззәтле дә кебек иде, әмма бу упкынның төбендә ут-ялкын көтеп торганны белсәң, бик куркыныч һәм бик дәһшәтле дә иде. Нигә Тимербулат шушы куркынычны тоймый соң, нигә Мәрьямбануны да шул юлга — динсезләр юлына өстери ул?

— Юк, Тимербулат, мин чишенер өчен киенмәдем... Минем өчен кеше сүзе түгел, Аллаһ сүзе мөһим. Мине шушылай кабул итәләр икән — кабул итсеннәр, юк икән, кеше фикере дип, мин Аллага каршы бара алмыйм.

— Миңа каршы бара аласыңмы? Дин бит иргә каршы барырга да кушмый.

Мәрьямбану төртелеп калды. Аннан авыр итеп сулап әйтеп куйды:

— Динемә тимәсәң, каршы бармам. Динемә тиясең икән, тидермәс өчен көрәшермен... Әмма минем синең белән көрәшәсем килми, Тимербулат. Мин синең дә шушы юлга килүеңне көтәм. Икебез ике юлда булсак, без бер-беребезне югалтырбыз кебек... Бергәләп намаз укырбыз, уразалар тотарбыз, дин юлында хезмәт итәрбез дип хыялланам мин...

— Нәрсә?! — Тимербулат сикереп үк торды. Аның эчендә тагы теге кара көч кайный, актарыла башлады. — Әйдә, икебез дә, тиле кебек, бит сыпырып утырыйк инде алайса! Кай арада шулай ычкынып өлгердең соң син? Тирә-ягыңа кара — кемең бар синең хәзер? Кемең бар?

— Мин бар.

Ир белән хатын, сискәнеп, икесе дә тавыш килгән якка борылып карадылар. Бүлмәсенең ишеге төбендә уллары Әхмәт басып тора иде. Ул әкрен генә диван почмагында бөкрәеп утырган әнисе янына килде, аның иңенә шуып төшкән ак яулыгын башына алып япты.

— Гел шулай йөр, яме, әнием. Син болай дөньядагы иң матур, иң, иң изге әни...

Мәрьямбану аягүрә торып басты. Улын кочагына алды. Улы үсеп, биегәеп киткән кебек тоелды аңа. Менә бит яшәүнең мәгънәсе нәрсәдә икән! Авыр вакытта килеп сыенырга сине аңлардай, яклардай балаң булуда! Алай гынамы, әле

атасы да аңлый алмаган олы хакыйкатьне аңларлык булып өлгереп җиткән улың булуда икән бит дөньяның иң зур бәхете! Яшәү мәгънәсе.

Мәрьямбану, сөенечен уртаклашырга теләгәндәй, яктырып Тимербулатка карады. Тимербулат телсез калган иде. Ул Мәрьямбануны гына түгел, улы Әхмәтне дә югалта баруын тойды, эчтән калтырап, тетрәнеп сизде-сизенде. Менә хәзер — бер адым, аларга таба атларга да, үзләрен кысып кочып, «мин дә сезнең белән, калдырмагыз мине берьялгызымны бу кара дөньяда» дип кенә әйтергә... Бер адым атларга...

Шулвакыт, стена аша, сузып-сузып эт баласы елый башлады. Стена аша Сигнал елый иде. Бу үксү авазы Тимербулатның миен телеп узды, җанына барып кадалды, яшерен уйларын уятты... Стена аша... Бөтенләй башка дөнья. Кайнап, ургылып торган дөнья. Билгеле һәм бөтенләй билгесез дөнья... Ул үзенең яшерен ләззәтләре, сер-сихерләре белән тимер кебек Тимербулатны да үзенә тарта, ымсындыра, чакыра иде... Ә Сигнал һаман елый да елый... Әллә аерылганын белеп елый, әллә аерыласына елый...

Бер адым ясалмады...

Вакытында ясалмаган шушы бер адым инде аларны бөтенләйгә, мәңгелеккә аерып ташлады...

* * *

Римма Тимербулатның эшен тиз тотты. Аның өчен мастерскойга кредит табу да, кирәкле кәгазьләргә кул куйдыру да берни тормый иде. Римма, гадәтенчә, иң югарыдагылар белән эш итте — түбәндәгеләр үзләре йөгерешеп йөрделәр. Римма өчен болар авыр булмады, аның өчен Тимербулатның игътибарын җәлеп итү авыр булды. Эшләренең шулай җайлы баруына канатланган Тимербулат тирә-юнендә беркемне күрмәде. Аңа хәзер Мәрьямбануның нишләп йөрүе дә, Римманың ниләр кылануы да — барыбер иде. Тимербулат, соңгы көчен-дәртен җыеп, башы-аягы белән эшкә чумды. Ул — ир-ат иде, янындагы вак-төякләрне онытып, ул тагы үз дөньясына кайтты — эшенә җигелде. Шундый зур хыяллар, уйниятләр белән булышырга алынган Римма да онытылды, бер читтә утырып калды. Әмма Тимербулат барысын онытса да, аны онытмаганнар иде. Фабарисов, әллә нинди усаллык, үҗәтлек белән гел Римманың исенә төшереп торды. Римма исә Фабарисов кушканга яки Фабарисов куркытканга түгел, үз җаны кушканга, үз җаны теләгәнгә Тимербулатка якынаерга җай эзли иде. Ул Тимербулатның юкка чыгуы белән ризалашырга теләмәде. Бу ирне якыннанрак белгән саен, Римманың аңа карата булган теләге һәм хөрмәте арта гына барды.

Римма исәбенчә, чын ир-ат нәкъ менә Тимербулат кебек булырга тиеш иде. Акыл дисәң — акылы зур, белем дисәң — белеме бар, эш рәте белә, үзе яшь, көчле, гайрәтле, саулык-сәламәтлеге ташып тора. Ул йөзе-бите, ул гәүдәләре... Барысы да Римманыкы булу, Римма кочагында иркәләнү, Римманы гына назлау өчен яратылган. Һәм шушы кеше, Римманың тилмереп теләгәне, шашынып көткәне, каргышлы тәкъдире — һәр көн башка ишектән кереп китә, башка хатын янына килеп ята, башка хатынны ярата. Хатыны да кем дисең? Бер дини фанатик, шәүләгә әйләнеп бара торган карачкы, яулык бәйләгән түмгәк... Римма аны бер тапкыр баскычта күреп егылып китә язды. Римма үзе кашын-күзен буямыйча, иреннәрен кызартмыйча чүп түгәргә дә чыкмый. Ә бу — ничек йокысыннан торган — шул кыяфәттә. Йөзендә ник бер буяу әсәре булсын! Өс-башында ник бер купшылык булсын! Әмма Римма күрде — бу хатынның зифа буен озын күлмәге дә яшерә алмаган. Аның ак мәрмәр йөзенә, каймалы куе керфекләренә бернинди дә буяу кирәкми, бу хатынның йөзе яулык астыннан да нур сирпеп тора иде. Мәрьямбануның күзләрендәге чиксез моңны, газаплы сабырлыкны күреп, Римма булып Римма куркып китте. Бу хатын тәнен чүпрәк-чапрак белән каплап куйса да, җанын каплый, яшерә алмаган шул, алардагы ялгызлыкны Римма шунда ук күрде, моның өчен сихерче булу да, күрәзәче булу да кирәк түгел, моның өчен хатын-кыз булу да җитә иде.

Римма Тимербулат тирәсендә ут булып бөтерелде, ялкын телләре кебек бәргәләнде, елан булып шуышты. Әмма Тимербулат өчен Римма бар кебек тә иде, юк кебек тә... Инде хатын-кыз буларак каратырга көче җитмәгәч, ул үзе белгән бөтен сихер-ырымнарны эшкә җикте — юлларына өшкергән сулар сипте, киемен төнәтмәләрдә төнәтте, бөтиләр төртте... Тик Тимербулат аның кочагына авып төшәргә ашыкмады. Римма янды, үз сихереннән үзе кипте, күзенә башка ир-ат күренмәс булды — әмма Тимербулатны үзенеке итә алмады. Аны Мәрьямбануның догалары бу хәлләрдән саклый идеме, Тимербулат үзе тимер кебек каты, бирешмәс идеме, ул һаман Римманыкы булырга ашыкмады. Риммадан ерак та китмәде, утында янарлык булып якын да килмәде. Бөтен шәһәрнең таныган экстрасенсы, күрәзәчесе, күпме халыкны сөйдерткеч-биздерткеч агулары белән тилертеп бетергән данлыклы керәшен хатыны бер ир-атны үзенә карату өчен көче җитмәгәнлеген сизде. Һәм ул соңгы адымга барырга булды.

Тимербулаттан ишетеп белүенчә, Мәрьямбану улы Әхмәт белән җәйгә ниндидер ислам лагерена тора киткәннәр иде. Римма бу хәлгә сөенеп бетә алмады, чөнки янәшәсендә Мәрьямбану булганда, ул беркайчан Тимербулатны үзенеке итә

алмасын аңлаган иде инде. Мәрьямбануның фәрештәләре Римманың җеннәренә караганда көчлерәк иде. Менә хәзер, Тимербулат берьялгызы калгач, Мәрьямбануның тәэсир көче юкка чыккач, Римма Тимербулатны үзенеке итү өчен барысын да эшләп караячак. Йә — хәзер, йә — беркайчан да... Римма әле, җиңелгәнен аңлап, кире дә чигенер иде, артта, үлем козгыны кебек, теге карт шымчы басып тора. Римманың үзен дә гарьлек буа башлады — шушы милләтче татарны да җиңә алмыймы ул? Данлыклы күрәзәче, сихерче, шәһәрнең иң матур хатын-кызы?! Әбисенең рухы белән ант итеп әйтә — ул моны эшләячәк!

Римма әбисе өйрәтеп калдырган соңгы алымга, соңгы юлга барырга булды. Бу эшне эшләү коточкыч нәрсә иде, бөтен чикләрне дә узу, мәңге кичерелмәс зур гөнаһ иде. Әмма үз бәхете хакына Римма бу адымга барырга булды. Ул бары тик шул бозым белән генә Тимербулатны мәңге Мәрьямбануга карамаслык хәлгә китерә ала иде, аны мәңгегә үзенә табындыра торган итә ала иде...

Әбисе, үләр алдыннан, аңа бу эшне өйрәтте, әмма беркайчан да файдаланмаска кушты. Чөнки кешене бу юл белән бозу — үзеңне дә, аны да тереләй үлемгә дучар итү дип аңлатты керәшен карчыгы. Әбисенең бу әйткәненнән ул вакытта Римма кычкырып көлде генә, чөнки үзенең кайчан да булса мондый түбән адымга барачагына ул ышанмый иде.

Һәм менә әбисенең үлем куркынычы белән тыйган алымы кирәк булып чыкты. Алай да Римма тота-каба гына бу эшкә тотынырга шүрләде, чөнки әбисе кат-кат кисәткән иде, бу эшне эшләсәң, исән чагыңда ук утта янасың дигән иде. Әмма Тимербулатны үзенә карату өчен Римманың башка чарасы калмады, төзәтә алмаслык хата икәнен белсә дә, ул бу адымга барырга булды. Алай да, бу хәвефле эшкә тотынганчы, тагы бер тапкыр әбисенең рухы белән киңәшеп карарга булды.

Мәетләрнең рухын чакыру серенә аны Таҗикстаннан кайткан татар качаклары өйрәткән иде. Бу якларда болай күрәзәчелек итүчеләр булмаганга күрә, халыкның көтү-көтү алар ягына агылуын күреп, Римма тизрәк үзе бу эшкә өйрәнергә булды. Кайда — куркытып, кайда зур акчалар төртеп, әйттерде ул таҗик татарларыннан тәлинкә серен. Өйрәнеп өлгерүгә, төннәр буе ду килеп мәетләр, рухлар белән сөйләшә, киңәшә башлады. Бу — бик куркыныч эш иде, монда бик тиз үзеңә дә ычкынырга мөмкин иде, әмма килгән халык аннан нәкъ шуны таләп итте, шуның өчен түләде.

Римма беркайчан да үзенең якыннарының рухларын чакырырга батырчылык итмәде. Бу юлы да утлар сүндереп, шәмнәр яндырып тәлинкә тәгәрәтергә утырганда, ул әбисе-

нең рухын борчырга батырчылык иткәне өчен курка һәм каушый иде. Римма почмакка карап чукынып алды һәм тәлинкәсен әйләндерә башлады. Шәмдәлләрдәге утлар бер янды, бер сүнде, бүлмәдә салкын җил исеп киткән кебек булды, күңел болгаткыч төче ис таралды. Әбисенең рухы риза түгел иде. Тәлинкә берничә тапкыр тәгәрәп идәнгә барып төште, бүлмәдәге шәмнәр сүнеп бетте, әмма карчык җавап бирергә ашыкмады. Инде булмады, туктатам дигәндә, Римманың колагына әбисенең тавышы ишетелгән кебек булды. Әмма бу — әбисе түгел, ә аның өрәге иде.

— Нигә борчыйсың? — диде ул бөтенләй чит тавыш белән.

Өрәк киткәнче, Римма сорап калырга ашыкты:

— Бу ир минеке булырмы?

— Синеке булыр. Әмма хатыны кочагында үләр. Бу эш бик тиздән булыр... Барыгыз да монда киләчәксез...

Бүлмәдәге соңгы шәм дә гөлт итеп сүнде. Тәлинкә идәнгә төшеп челпәрәмә килде. Римма дөм караңгыда берүзе утырып калды. Колагында һаман куркыныч сүзләр сулкылдады. «Хатыны кочагында үләр... Бу эш бик тиздән булыр...» Нәрсә әйтергә теләде өрәк? Тукта, ул бит «Синеке булыр» дигән сүзләрне дә әйтте! Римма терелеп, уянып киткән кебек булды. Аның өчен иң мөһиме — шушы сүзләр иде. «Синеке булыр!» Тимербулат аныкы булсын өчен Римма соңгы серен, соңгы сихерен кулланачак. Аның хатыны кочагында үлгәнен көтеп тора алмый ул. Ул Мәрьямбану белән Тимербулатны барыбер аерачак, җәннәт белән җәһәннәмне бергә кушачак, бу тәкәббер ирне үзенеке итәчәк! Итәчәк!

Күктә ай тулды. Ул көн килде. Эштән арып кайткан Тимербулатны Римма үзләренә чәй эчәргә чакырды. Тимербулатның биредә элегрәк тә булганы бар иде, күршесенең эчкерсез ярдәменә рәхмәтләрен бу бүлмәдә ул инде күп тапкырлар әйтте. Эш шул рәхмәт әйтешүләрдән ары узмады. Риммага бу гына җитмәвен, үзенең дә әкренләп бу үткен хатынга ияләнә баруын сизенә иде Тимербулат. Әмма бу юлы Римма янына бөтенләйгә керүен белми иде әле ул. Римма ясап биргән сәер чәй гаепле идеме моңа, ялгызлыкмы, Римманың шулай ымсындыргыч булуымы — Тимербулат үзе дә аңламыйча калды. Ул әйтерсең лә мәңге айнытмый торган йокы даруы эчкән иде... Шушы керүеннән ул инде тимер дә түгел, булат та түгел, эреп изрәгән измә иде. Аннан нәрсә әвәләргә дә, ничек әвәләргә дә була иде... Мәрьямбану белән бергә узган гомер арасына да пәрдә төште, араларына таш стена басты, бергә тормыш башлаган ир белән хатын берсе — дин юлыннан, икенчесе — җен юлыннан китеп барды... Һәркем үз юлын үзе сайлады...

* * *

Ул җәйне Мәрьямбану балалар белән җәйге ислам лагерена киткән иде. Балалар дигәне — Әхмәт һәм аның дуслары Хәйдәр белән Ләйлә иде. Дөрес, Ләйләнең әнисе кызын бер дә мөселман лагерена җибәрәсе килмәгән иде, Мәрьямбану үзе барганга гына ышанып җибәрәсе булды. Ул аны һаман техникумда директор дип уйлый иде, ахры. Мәрьямбану исә үзенең эштән киткәнен беркемгә дә сөйләмәде, хәтта Тимербулат та аны каникулда дип белә иде. Хәйдәрнең әнисе исә улын аларга тагып диярлек җибәрде. Бу гаиләгә бик зур фаҗига килгән иде — Хәйдәрнең әтисе кеше таптаткан, хәзер суд көтеп, Минзәлә төрмәсендә ята иде. Әнисе көне-төне шуның артыннан чаба, адвокат эзли, акчасын таба, әйберләрен төяп, Минзәләгә чыгып йөгерә. Буй җитеп килгән Хәйдәрне карарга хәзер аның вакыты да, мөмкинлекләре дә юк. Шуңа күрә ул Мәрьямбануга ялынып диярлек Хәйдәрне биреп җибәрде. Ә Әхмәткә инде әйтеп тә торасы юк иде, ул бу ислам лагере турында мәдрәсә шәкертләреннән үзе ишетеп кайткан, үзе дәртләнеп барысын да оештырып йөрде, әнисен дә шунда барырга үгетләде. Мәрьямбануның техникумнан китеп, эшсез йөргән вакытлары иде. Кая гына барып караса да, хәбәре үзе белән йөрде, үзенә ияреп йөрде. Дәүләт уку йортларында белем бирү, укыту турында уйларга да ярамый иде, алар яулык ябынган хатын-кыз белән сөйләшеп тә тормадылар. Марҗа җитәкчеләр исә, «Бездә дин укытылмый» дип, Мәрьямбануны ишек төбеннән үк борып җибәрергә ашыктылар. Мәрьямбану үзенең биолог-галим булуын әйтергә тырышса да, аны тыңлаучы булмады, андый галимнәр соңгы елларда эш эзләп көтүләре белән йөриләр иде...

Бу лагерьга Мәрьямбану аптыраганнан гына килде. Өйне ташлап чыгып китәсе килмәгән иде аның. Дөрес, Тимербулатның эшләре җайланып китте китүен, әмма ул элеккеге Тимербулат түгел иде инде. Ул, барысыннан да берьюлы котылырга теләгәндәй, башы-аягы белән эшкә чумды. Хәзер милли хәрәкәт, сәясәт дип авыз да ачмый, дин турында да телгә алмый, ник алай йөрисең, ник болай йөрисең дип тә Мәрьямбануга бәйләнми. Әйтерсең лә аның янәшәсендә хатыны бөтенләй юк, әйтерсең лә Мәрьямбану шәүлә генә, җансыз гәүдә... Ярты җәе шулай иреннән бер җылы сүз ишетмичә үтеп киткәч, Мәрьямбану улының чакыруына риза булды, Тимербулатны да үзе теләгән ялгызлыгында калдырды. Бәлки, бу вакытлыча гына аерылып тору аларны яңадан якы-

найтыр дип уйлады ул, һәрберсенә тукталып уйланырга мөмкинлек бирер, яңадан сагындырып кавыштырыр? Әмма бу аерылып торуның инде мәңгелек булуын, аларны яңадан бары тик үлем генә очраштырасын, кавыштырасын Мәрьямбану әле белми иде...

Бу лагерьда Мәрьямбану үзе өчен бөтенләй яңа дөнья ачты, соңгы вакытта җаны бәргәләнә-бәргәләнә, өзгәләнә-өзгәләнә эзләгән тынычлыкны тапты. Иң мөһиме — ул ялгызлыгыннан котылды. Ул үзенең дингә әле тышкы яктан гына килүен аңлады, күңелендәге бу тотрыксызлыкның, туктаусыз хәвеф-борчуның да шуннан икәнен белде. Яулык бөркәнү дә, хәтта намаз уку да әле зур инану, ышану булмаска мөмкин икән... Иң мөһиме — бөтен акылың, җаның-тәнең белән Аллаһның барлыгын тою, дөньяның шушы нигъмәтләрен биргән өчен Аны чиксез ярату һәм Аның бәддогасыннан курку иде. Фикерләве белән шушыларга ирешкән, Аллаһка шушындый ышану белән ышанган кеше дин юлында туган бөтен авырлыкларга, каршылыкларга түзә, ул кирәк вакытта сабыр итәргә, кирәк вакытта көрәшеп җиңәргә өйрәнә икән. Лагерьга җыелган үсмерләрне гарәп галимнәре динне әнә шулай аңларга, шулай тотарга, тормышта бары тик Аллаһы Тәгалә кушканча гына яшәргә өйрәттеләр. Балалар белән бергә, Мәрьямбану да парта артына утырды, әлифба өйрәнде, кулына Коръән алды. Энҗе бөртекләре кебек тезелеп киткән гарәп хәрефләрен җыеп, беренче тапкыр үзе Коръән аятьләре укыгач, ул елады. Шушы изге китапны күкрәгенә кочып үлгән әби-бабаларын күз алдына китерде, бер кулга кылыч, бер кулга Коръән тотып Казан өчен сугышкан татарларны исенә төшерде. Чукынудан качып, дөнья буйлап сибелгән татарларны, дин өчен Себер киткән, шәһит булган милләттәшләрен күз алдына китерде... Соңгы йөз елда шушы изге китаптан, Аллаһның диненнән башка яшәргә тырышкан татар халкының нинди фаҗигаләргә барып җитүен аңлап елады Мәрьямбану. Һаман шушы имансызлык юлыннан барса, татар бетәчәк иде, әмма йөз ел буе динсез яшәгән милләтне дөрес юлга кертергә дин әһелләренең генә көче җитми иде. Алар бит әнә нинди аз — тамчы бөртекләре кебек кенә. Әле алары да аерым-аерым. Димәк, милләтнең әхлагын, дин мәсьәләсен бөтен дәүләт белән күтәргәндә генә, дәүләт дәрәҗәсендә хәл иткәндә генә әле нәрсәнедер үзгәртергә өмет бар. Әмма бу дәүләткә татарның динле булуы кирәкме соң? Динле кеше бит ул эчми, ә дәүләтнең казнасы яртылаш аракы саткан акчадан тора. Динле кеше дуңгыз итенә, харам ризыкка якын бармый, ә дәүләт халык-

ны очсызлы дуңгыз итендә, харам ризыкта тота. Динле кеше, иң беренче чиратта, Аллаһ кушканча, Коръәндә язылганча яши, ә дәүләткә халыкның алар кушканча, алар боерганча яшәве кирәк. Димәк, халык дингә кереп китә икән, дәүләт, элеккечә, динсезлектә кала икән, иртәме-соңмы алар арасында каршылык туарга мөмкин. Йә — дәүләткә исламча булырга, йә — халыкка яңадан исламнан чыгарга туры киләчәк. Бу илдә моның кайсы мөмкин? «Берсе дә мөмкин түгел, — дип уйлады Мәрьямбану ачынып. — Кяфер дәүләте исламча була алмый, дингә килмәгән халык та исламнан чыга алмый...»

Ихлас күңелдән укып йөргән бу яшьләргә карап, бер яктан, сөенсә, икенче яктан, Мәрьямбануны борчу да баса иде. Менә бу татар яшьләре күз алдында дингә киләләр — Коръән укыйлар, намазларын калдырмыйлар, исламча киенә, исламча яши башладылар. Берничә елдан болар урта мәктәпне, татар гимназияләрен тәмамлап чыгачаклар. Аннан соң нәрсә көтә бу балаларны динсезләр арасында, кяферләр илендә? Кайларга укырга керерләр алар, кайларга эшкә урнаша алырлар? Бер яулык бөркәнгәне өчен генә Мәрьямбану үзенең дусларына чит булды, аны эшеннән китәргә мәҗбүр иттеләр. Ә унөч-ундүрт яшьтән яулык бөркәнгән бу кызларны алда нәрсә көтә? Анасы базарда аракы сатып торган менә бу Ләйләне нәрсә көтә? Атасы төрмәдә утырган Хәйдәрне нәрсә көтә? Дингә шулхәтле ихластан, бөтен җаны-тәне белән кереп барган үз улы Әхмәтне нәрсә көтә? Атасы бит аны бизнеста үзенә ярдәмче булыр дип өмет итә, инде институтта да сөйләшеп куйган. Ул аны мулла булыр дип, яки кайдадыр дин өчен үлеп калырга дип үстерми, үзенә ярдәмче, таяныч булыр дип үстерә...

Мәрьямбануның вакыт-вакыт уй дәрьясына төшеп батуын күреп, улы Әхмәт үзе аңа ярдәмгә килде. Инде унбишенче яше белән барган улына Мәрьямбану дөресен әйтте. Аларның киләчәге өчен борчылуын, хәвефләнүен сиздерде.

— Барысы да Аллаһ кулында бит, әнием, — диде Әхмәт, әнисен олыларча юатып. — Син кара әнә, йорт тулы наркоман, адым саен кеше үтерәләр, кеше талыйлар — аларны нинди киләчәк көтә?

— Шулай, улым, андый хәлгә төшүдән Аллам сакласын... Әмма дин дип бөтенләй үк дөньядан да аерылырга ярамый, ахры... Менә минем хәлемә кара.

— Бу хәлдә калуыңа син гаепле түгел бит, әнием. Әгәр алар да дини булса, яулык бөркәнгән өчен генә сине эштән җибәрерләр идеме? Менә хәзер аңладыңмы инде «Милләт,

бәйсезлек!» дип кычкырып йөрүләреңнең буш эш булуын? Ялгышыңны аңладыңмы?

Мәрьямбану гаҗәпләнеп улына карады. Нинди ялгыш? Соң алар бит бергәләп шушы бәйсезлек өчен, татар мәктәпләре, татар теле өчен көрәштеләр, улы да, ире дә һәрвакыт аның янәшәсендә булдылар. Нинди үкенеч, нинди ялгыш турында сөйли бу бала?

— Ни сөйлисең син, улым? Бәйсезлек булмаса, менә болары да булмас иде бит...

— Бәлки, нәкъ менә шушылардан башларга кирәк булгандыр, әнием? «Азатлык» дип кычкырганчы, башта «Аллаһ!» дип әйтергә кирәк булгандыр? Сез исерек милләткә бәйсезлек алып бирергә тырыштыгыз. Бәлки, башта аны иманга чакырырга кирәк булгандыр?

Мәрьямбану дәшмәде. Ул белә — улы аны гаепләми иде. Әхмәт җавап эзли. Әхмәт бары тик хакыйкатьне эзли иде. Һәм ул хакыйкатькә ата-анасына караганда якынрак тора кебек иде...

— Без эшне Коръән белән алып барачакбыз, әни, — диде ул. — Тик шушы Коръәнне, милләтебезне яклау өчен, аны коллыктан коткару өчен, икенче кулда кылыч та булырга тиеш. Татар ирләре гомер буе шулай эшләгәннәр, без дә моңа әзер булып торырга тиеш...

Мәрьямбану каршында бөтенләй башка кеше басып тора иде. Әйтерсең лә бу татар баласында Колшәрифләр, Батыршалар рухы телгә килгән иде, тамырларында меңьеллык татар каны, көрәшчеләр каны аккан бу ир бала милләте өчен, дин өчен утка керергә дә әзер иде. Мәрьямбану курыкты да, сөенде дә. Бу — аның улы, әмма ул белмәгән татар иде. Азатлык өчен мәңгелек газават юлына чыккан татар иде. Бу юлның аны Идел буйларыннан Каф тауларына алып барасын, башка милләтнең азатлыгы өчен сугыш утларына кертәсен, җирдәге шушы мәхшәрдән, җәһәннәмнән мәңгелек җәннәтләргә күчерәсен әле ана да, бала да белмиләр иде...

...Урман аланы татар яшьләре белән тулган. Көне буе дин дәресләре алганнан соң, алар ял итә. Кайберләре бер читтә һаман Коръән укый, Коръән өйрәнә, кайберләре спорт белән шөгыльләнә, күпчелек үзара сөйләшеп, бәхәсләшеп гөр килә. Монда әдәпсезлек, әхлаксызлык юк, монда мәгънәсезгә вакыт уздыру, көннәр буе музыка дөңгердәтеп, күңел ачулар юк, төнге җыр-биюләр, дискотекалар юк. Яшьләрнең күңелләре болай да ачык — гыйлемгә, яхшылыкка, изгелеккә... Читтән караганда, кемдер өчен болай ял итү, яшәү бик күңелсез дә тоелырга мөмкин. Андыйларны монда озак то-

тып булмый, лагерьдан да ике-өч көн эчендә ташлап кайтып китүчеләр булды. Көннәр буе гарәп хәрефләре, Коръән өйрәнүгә, төннәр буе намаз укуга күпләр түзә алмады. Түзгәннәр — калды, алай гынамы, гомеренең бер генә мизгелен дә әрәмгә уздырырга теләмичә, бөтен көчен куеп дин гыйлеме алырга омтылган татар балаларын күрде монда Мәрьямбану. Бигрәк тә ир балалар арасында андый үсмерләр күп иде. Алар беренче генә елларын укымыйлар, күрәсең, Коръәнне, динне яхшы беләләр, башкалар арасында да туктаусыз аңлату, өйрәтү эшләре алып баралар. Унбиш-уналты яшьлек татар балаларының шундый ихлас һәм җитди рәвештә дин тотулары, алардагы тәртипне, әдәпне күреп, Мәрьямбану бер фикергә килде. Милләтнең киләчәге менә шушындый иманлы һәм милли балаларда иде. Мәрьямбану шунысына да куанды — бу балаларның күбесе татар гимназияләре, татар мәктәпләре укучылары иде, алар да теге вакытларда ата-аналарына ияреп, митингларга йөрделәр, ата-аналарына ияреп, бәйсезлек өчен көрәштеләр. Аларны еш кына «бәйсезлек балалары» дип йөртәләр иде. Бу балаларга бәйсезлек сукмаклары гына тар булып тоелган, алар мәңгелек бәхет юлына чыкканнар... Тагы берничә ел үткәч, шушы «бәйсезлек балалары»ның, кулларына корал тотып, башка милләтнең бәйсезлеге өчен сугышасыларын әле Мәрьямбану күз алдына да китерми иде...

Мәрьямбануның галим кеше икәнлеген белгәч, лагерьда аңа да эш таптылар. Үзе дин дәресләре алу белән берлектә, ул балаларга биология буенча, үсемлекләр, тереклек дөньясы турында дәресләр бирә башлады. Техникумнан аермалы буларак, ул инде боларның барысына да ислам күзлегеннән чыгып бәя бирә иде. Фәнне дин белән баеткач һәм дәлилләгәч, бу дөнья тагы да яктырып, нурланып киткән кебек булды. Мәрьямбану Коръәндә иксез-чиксез гыйлем дәрьясы ачты, тормыштагы тәҗрибәсен, дөньяви белемнәрен дә кушып, ул балаларга да шушы бөек хакыйкатьне җиткерергә тырышты. Бу дөньяны, җиһанны, бөтен тереклек ияләрен, үсемлекләрне, адәм баласын Аллаһы Тәгалә барлыкка китерүен, тотып һәм саклап торуын аңлата алды ул балаларга. Кулына Коръән тотып аңлатты, фәндә һәм тормышта үзе белгәннәрен дәлилле-дәлилле сөйләде, аны беркем дә «болай сөйләмә» дип тыймады, бер сүзе өчен дә ул соңыннан кызарып-борчылып йөрмәде. Менә шушы мизгелләрдә инде Мәрьямбану үзенең нәрсә өчен туганын, бу дөньяда нәрсә эшләргә тиешлеген аңлады — ул кешеләргә Аллаһның хөкемнәрен җиткерергә тиеш иде. Хәтта моңа кадәр алган дөньяви бе-

лемнәре дә Мәрьямбану өчен файдага булды, ул үз өлкәсендә зур белгеч иде, хакыйкатькә ирешү өчен аңа бары тик Коръән гыйлеме генә җитмәгән булып чыкты.

Мәрьямбануны көзгә мәдрәсәгә эшкә чакырдылар. Ул шушында дин гыйлеме алырга һәм, шул ук вакытта үзе дә балаларга фәнни дәресләр бирергә тиеш иде. Мәрьямбануның активлыгын, эш рәте белүен күреп, ректорга оештыру эшләрендә булышуын үтенделәр. Мәрьямбану сөенә-сөенә риза булды. Ниһаять, ул үзенең эзләгәнен тапты, ни өчен яшәгәнен аңлады. Ул бүгенге көннән ялгыз түгел иде, аның үзе кебек үк дин тоткан, яулык бөркәнгән, бары тик Коръәнчә генә яшәргә омтылган мөселман кардәшләре бар иде. Соңгы вакытта гел этелеп-төртелеп, кадерсезлектә йөргәннән соң, ул тагы үзенең кешеләргә кирәклеген аңлады, милләтнең гел исерекләрдән һәм имансызлардан гына тормаганлыгын күрде, ул тагы тормышның, яшәүнең кадерен, ләззәтен сизә башлады…

Мәрьямбану лагерьдан бөтенләй икенче кешегә әйләнеп кайтты. Соңгы вакытта өстенә ишелеп килгән бу үзгәрешләрдән, тетрәнүләрдән ул үзе дә югалып калган иде. Әйтерсең лә ул шушы арада бер дөньядан икенчесенә күчте, бер вакыт үлчәмен икенчесенә алыштырды. Әйтерсең лә аның өченче күзе — күңел күзе ачылды. Мәрьямбану инде үзе дә башка иде, ул дөньяга да башкача карый башлады. Ул юккабарга борчылудан, хәсрәтләнүдән арынды. Иртәгә ни булыр дигән хәвефле уйлары, шик-шөбһәләре юкка чыкты. Иртәгә ни генә булса да, Мәрьямбану ихтыярында түгел иде. Болар барысы да Аллаһ кулында һәм барысы да нәкъ Ул дигәнчә булачак иде. Бәндәсе өчен нәрсәнең хәерле булуын бары тик Аллаһы Тәгалә генә белә иде. Моңа бик нык ышанырга һәм үзеңне тулысынча Аңа тапшырырга кирәк иде. Мәрьямбану иртәгәсе көн өчен хәсрәт утларында янмыйча, бүген булганына сөенеп, шөкрана кылып яшәргә өйрәнде. Ул һәр туган яңа көнгә сөенде, һәр көнне мәгънә белән, изге гамәлләр белән уздырырга тырышты, һәр кичне Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтләрен әйтеп йокыга китте. Иң мөһиме — Мәрьямбану үзенең янәшәсендә киңәшә-таяна алырлык изге баласын — улын күрде, бу юлда аны тапты. Алар бергәләп намаз укыдылар, бергәләп Коръән өйрәнделәр, бергәләп милләт язмышы турында сөйләштеләр. Һәм Мәрьямбану үзенең иң бәхетле ана икәнен аңлады, шушындый изге угыл биргәне өчен Аллаһы Тәгаләгә чиксез рәхмәтләрен әйтте.

Шушы зур шатлыгын ире Тимербулат белән дә уртаклашасы килде аның. Лагерьдан ул өенә очып диярлек кайтты.

Ул яңадан элеккеге Мәрьямбануга әйләнгән иде — ачык күңелле, шат, бәхетле Мәрьямбануга. Ире белән аңлашмыйча, эндәшмичә, сөйләшмичә йөрүләре аңа вак һәм мәгънәсез нәрсәләр булып күренде. Ул хәзер үзе башлап эндәшәчәк, үзе Тимербулатның җаена торырга тырышачак, хәзергә диндә булмаса да, дингә килүен көтәчәк, ярдәм итәчәк. Баласының атасы булганы өчен, никахлы ире булган өчен, яраткан кешесе булганы өчен...

Әмма Тимербулат ул төнне йокларга өйгә кайтмады. Икенче кичне Мәрьямбану аны эш урынына эзли чыгып китте, әмма ире анда да юк иде. Мәрьямбану тизрәк өенә ашыкты, Тимербулат инде кайткандыр да көтеп утырадыр кебек тоелды аңа. Шулай ашыгып кайтып килгәндә, каршыннан парлап атлаган ир-ат белән хатын-кызны күреп, таштай катып калды Мәрьямбану. Кичке эңгердә дә ул иренең газиз гәүдәсен, атлап йөрешләрен танып алды. Алар бер-берләренә сыенып беткәннәр, башларын башка терәп, кочаклашып диярлек кайтып киләләр иде. Алар Мәрьямбануны күрмәделәр. Әйтерсең лә Мәрьямбануны кемдер, бауга бәйләгән кебек, алар артыннан өстерәп алып бара иде. Бергәләп караңгы подъездга килеп керделәр, бергәләп лифтка утырдылар. Югыйсә Мәрьямбануга баскычтан менеп китәргә дә була иде бит, шулай итәргә кирәк тә иде, күрмичә дә калырлар иде. Менә хәзер бер арбада, кемдер — бәхетенең, кемдер — бәхетсезлегенең җиденче катына менеп бара... Ике хатын һәм бер ир... Бер мизгеллек бу күтәрелеш Мәрьямбану өчен бер гасырлык газаплы юл булып тоелды. Ул күзләрен күтәреп карарга оялды, үзен утка төшкән кебек хис итте, кая басса да аларга килеп орынырмын дип курыкты.

Инде Тимербулат та аны күргән иде. Ул, күзләрен зур итеп ачып, ниндидер афәт көткәндәй, Мәрьямбануга карап катты. Ул аның нәрсә булса да әйтүен, бер дә булмаса, кычкыруын, ярсуын көтте. Тимербулат аңа да әзер иде. Әмма Мәрьямбану дәшмәде. Ут булып янган йөзен ак яулыгына яшереп, бу газаплы сәяхәтнең ахырын көтте ул. Римма да чытлыклануын, Тимербулатка сырпалануларын туктатып торды. Ул да ахыры ни белән бетәсен көтә иде. Ул инде максатына иреште — Тимербулатны үзенеке итте. Аның мәңге үзеннән китә алмасын Римма яхшы белә иде һәм шуңа күрә тыныч кына аларны күзәтте.

Шулчак Мәрьямбану түзә алмады, керфекләрен күтәреп карады. Тимербулат та, оялып һәм әрнеп, аңа карап тора иде. Ул Мәрьямбануның озын керфекләрендә тамам-тамам дип торган яшь бөртекләрен күрде. Бу энҗе бөртекләре аның

мәрмәр йөзеннән тәгәрәп төшәрләр дә, Тимербулат белән Римманың аяк астына түгелеп, әрәм булырлар кебек иде. Мәрьямбану башын югары күтәрде. Бер бөртек яше дә җиргә таммады, аяк асларына төшмәде...

Менә алар, дәшми генә, җиденче катка менеп җиттеләр. Мәрьямбану, ашыгып, үз ишегенә юнәлде, Римма — үз ишегенә. Тимербулатның сындай гәүдәсе, ике ишек арасында адашып, басып калды. Бер якка — кан, икенче якка — җан тарта иде... Хатыннарның икесе дә дәшмәде. Икесе дә үз ишегеннән кереп китте. Тимербулат шул урында басып калды...

Мәрьямбану төне буе көтсә дә, Тимербулат кайтмады...

Мәрьямбану аңлады — бу инде аның кайтмаска дип китүе иде...

* * *

Мәрьямбану Фабарисовның тормышына ничек килеп кергән булса, шулай юкка да чыкты. Техникумга комиссия артыннан комиссия җибәрсә дә, ул Мәрьямбануны аннан тиз генә китеп барыр дип уйламаган иде. Чөнки Мәрьямбануның бөтен тормышы, фәнни карьерасы шушы техникум белән бәйләнгән иде, аның ничек итеп бер уку йортына татар телен кертүен бөтен республика, зыялылар күзәтә иде. Һәм шул Мәрьямбану беркөнне киткән дә барган. Үзенең арттырыбрак җибәрүен Фабарисов та сизде, чөнки Мәрьямбану өстеннән имзалар җыюны да, наркотиклар ташлауны да ул оештырган иде, аның исәбе — бары тик бу башбирмәс хатынны бераз куркыту, кулга ияләндерү генә иде. Ә ул әнә китеп үк барган...

Мәрьямбану теге вакытта ничек кенә йөзенә бәреп әйтсә дә, ничек кенә мыскыл итсә дә, Фабарисов аны һаман оныта алмый иде. Ул Тимербулатның Римма белән яши башлавын да, Мәрьямбануның ялгыз калуын да белә иде инде. Бу хәл аны тагы да өметләндереп җибәрде, Мәрьямбану турында дингә киткән икән, барысы белән дә арасын өзгән икән дигән сүзләр йөрсә дә, ул аларга ышанмады. Мәрьямбану кебек хатын дөнья белән арасын өзә алмый иде, Мәрьямбану кебек хатын ялгыз яшәргә тиеш түгел иде.

Берара ул Мәрьямбануның эзен югалтты. Һәм иснәнеп, тагы милли хәрәкәт җыелышына барып чыкты. Әмма бу инде элеккеге еллардагы милләтчеләр түгел иде. Бәйсезлек алабыз дип йөреп тә, башлары белән стенага килеп бәрелгән милли хәрәкәт бер мәлгә югалып калган иде. Бер караганда,

мөстәкыйльлек тә бар кебек — Татарстанның үз байрагы, туграсы, гимны бар, Конституциясе, хәтта Президенты да бар. Әмма, икенче яктан караганда, Татарстанның бернинди бәйсезлеге дә юк — салымнарны элек Мәскәү ничек алса, шулай каера бирә, элек ничек Россия армиясенә солдатка алсалар, хәзер дә шулай... Бәйсезлектән халык баемады, киресенчә, инде ике хуҗага бил бөгә башлады. Милләтчеләрнең бөтен тырышып йөрүләре бер төркем кешегә власть алып бирүгә кайтты да калды. Аннан инде алар милләтчеләрдән сорап тормадылар, Мәскәүдән калган байлык, бөтен мал-мөлкәт хакимият тирәсендә йөрүче туган-тумача кулына күчте дә бетте. Хәзер милләтчеләр менә шул хакта каравыл кычкыралар, төрле җирләргә шикаятьләр язалар. Әмма язган бер кәгазьләре шушы ук карак түрәләр кулына әйләнеп кайта иде...

Моның шулай икәнен Фабарисов үзе дә белә иде. Ул бу «яңа байлар» өстеннән дә кайбер хәбәрләрне җыйгалап барды. Сталин заманы булса, күптән төрмәдә черисе иде инде алар. Әмма язмышның көлүедер инде бу — Фабарисов службасы нәкъ менә шушы каракларны сакларга, якларга тиеш. Ягъни һәртөрле милләтчеләр һөҗүменнән, террористлардан, фанатлардан, вак-төяк каraклардан — шушы властьны сакларга тиеш.

Мәскәүгә карата янау-таләпләре игътибарсыз кала башлагач, милләтчеләр урындагы җитәкчеләрне тәнкыйтьләргә тотындылар. Имеш, алар бәйсезлекне Мәскәүгә саткан, имеш, алар үз халкын талый, имеш, милләткә төп куркыныч шушы татар түрәләреннән килә...

Менә шундый чакларда инде Фабарисов колакларын торгыза. Берәрсе корал күтәрергә чакырмасмы, властьны, Президентны бәреп төшерик дип әйтмәсме, сугышка өндәмәсме? Юк, милләтчеләр һаман кәгазь яздылар, имза җыйдылар, митинг-пикетларга чыгып баскан булдылар... Кыскасы, алар өрә торды, бүреләр йөри торды... Милләт тормышында инде берни дә үзгәрмәс, кемнән нәрсә көтәргә — инде барысы да билгеле, ачыласы ачылып беткән кебек иде. Әмма төп көч, Россия өчен дә, Фабарисов өчен дә төп куркыныч бик тирәндә, милләтнең һич көтелмәгән катламнарында яшеренеп, үз вакытын көтеп яткан икән... Монысын беркем дә — Россия ФСБсы да, Татарстан җитәкчеләре дә, Фабарисов үзе дә көтмәгән иде...

Дөресен әйткәндә, Фабарисов аларны менә бу милли хәрәкәттә күрмәде дә. Күрсә дә игътибар итмәгәндер, чөнки ул вакытта аларга ата-аналарына ияреп йөрүче бала-чага итеп

кенә карый иде Фабарисов. Менә шул «бәйсезлек балалары», ата-аналарына ияреп пикет-митингларга йөргән татар малайлары, беренче чечен сугышына, чеченнарны яклап, корал тотып килеп кермәсеннәрме?! 1994—1996 елгы урыс-чечен сугышында Чечняны яклап шәһит китүчеләрнең күпчелеге татар егетләре икәнлеге беленгәч, Россия органнары шашып калдылар! 1996 елның алтынчы августында Грозныйны федераль гаскәрләр кулыннан тартып алуда, чеченнар ягыннан йөзләгән татар егете дә катнашканлыгы билгеле булды. Урыс гаскәренең хурлыклы җиңелүендә мөселман-татарларның роле әйтеп бетергесез зур булуын шул чагында ук яхшы аңладылар Россиядә. Тик шуны гына аңламадылар — ничек бу татарлар, үзләрендә, Татарстанда, карап торып бәйсезлекләрен юкка чыгардылар соң? Барысы да иң башта Россиядән Чечня түгел, Татарстан чыгып китәр дип көткәннәр иде бит. Юридик яктан Татарстанның моңа бөтен мөмкинлекләре бар иде, ә алар, шулхәтле зур авырлыклар белән, ничә гасырлар көрәшеп алган бәйсезлекләрен угрылар кулына тапшырдылар да тынып калдылар? Башка халыкның иреге, бәйсезлеге өчен Каф тауларына килеп башларын салганнар, ә үзләрендә булган бәйсезлекләрен, ирекләрен карап торып юкка чыгарганнар? Нинди милләт бу татарлар? Мәскәү бит аларны җырлап-биеп, гармун тартып йөриләр дип кенә уйлаган иде, ә алар әнә шул арада сугыш утларына барып керерлек яшьләр тәрбияләп өлгергәннәр! Кайда, кайчан, кемнәр тарафыннан — боларның барысына да урындагы спецорганнар, Фабарисовлар җавап бирергә тиеш иде, чөнки татарлар арасыннан шушындый Аллаһ сугышчылары үсеп җиткәнгә Фабарисовлар да гаепле иде... Һәрхәлдә, моны Мәскәүдән бик яхшы сиздерделәр, кисәттеләр, хәтта янадылар да. Алар әйтүенчә, шушы елан оясында яшәп яткан Фабарисов йә бу еланнарны юк итә, тотып бирә, йә еланнар оясы, шәһәре-ние белән юк ителәчәк. Мәскәү мондый сүзләрне уйламыйча гына әйтми иде. Мәскәү әйткән сүзен тормышка да ашыра бара иде...

Чечняны яклап йөзәрләгән татар егетләре сугышканын ишеткәч, Фабарисов үзе дә бер мәлгә телсез-өнсез калды. Җитмәсә, аларның күпчелеге Кама аръягыннан — шушы Чаллы, Әлмәт, Бөгелмә тирәләреннән икән. Кулга корал алып сугышырлык булып кайларда, нинди гаиләләрдә, нинди оешмаларда тәрбияләнеп җиткәннәр алар? Башка милләтнең бәхете өчен үлемгә барырлык итеп тәрбияләү өчен нинди бөек идеологияләр, көчле тәгълиматлар, оста тәрбиячеләр кирәк булгандыр? Кайда ул кешеләр, кайлардан эзләсен алар-

ны Фабарисов?! Милли хәрәкәт җыелышларына да ул, нигездә, шуларны белер, иснәнер өчен йөрде. Әмма нигездә әбисәбиләргә һәм мактанчык надан татарлар кулына калган милли хәрәкәттән эзләргә кирәк идеме соң бу «Аллаһ сугышчылары»ның эзләрен? Юк, әлбәттә, юк... Органнарда гомер буе эшләү тәҗрибәсе аны милли хәрәкәткә дә түгел, татар мәктәпләренә дә түгел, хәтта мәчетләргә дә түгел, мәдрәсәләргә алып китте. Эт сизгерлеге белән сизә Фабарисов — шушыннан, шушыннан эзләргә кирәк үлемнән курыкмый торган татар яшьләрен! Җырлап-биеп, гармун күтәреп йөрүчеләр, хәтта байрак болгап йөрүчеләр дә күрәләтә үлемгә китмәсләр, уенга әйләнгән шушы өч тиенлек тормышлары кадерле аларга. Мәчеттә сәдака җыеп утыручы мулла-мунтагай да чыгып китмәс җиһад дип. Алар да инде бу тормышка җайлашып, кайда җырлап, кайда елап, кайда Аллаһ исеме белән бит сыпырып, кирәк булса бер-берләрен бик яхшылап кына сатып, шыпырт кына яшәп яталар. Фабарисов аларның барысын да белә, барысы да әләк белән аңа йөгерәләр, аңа киләләр. Ә менә мәдрәсәләр барысыннан да бер читтә тора. Аларга милли хәрәкәт тә кирәкми, алар сәясәткә, шәһәр тормышына да катнашмыйлар кебек, плакатлар күтәреп урамнарга да чыкмыйлар, акча юк, ашарга юк дип тә елап йөрмиләр. Коры бәрәңге белән ипи ашап, беркем белән аралашмыйча, баш күтәрми Коръән өйрәнәләр дә Коръән өйрәнәләр. Укытучылары — гарәпләр. Нәрсә өйрәтәләр аларга ул чүл гарәпләре, нәрсә язылган ул Коръәндә — аны бит татар халкы белми, аны әле Фабарисов үзе дә белми! Аларның нәрсә сөйләшкәннәрен дә аңлаучы юк, бер ел укыган шәкертләренә хәтле гарәпчә сөйләшергә тырыша. Монда стукачшымчылар кертеп эшләтүе дә бик авыр — чит телләр белгәне бу кечкенә шәһәрдә череп, шәкертләр артыннан иснәнеп ятмый, Казанга, Мәскәүгә, чит илләргә китә. Тел белмәгән шымчыларга монда керүдән мәгънә юк — ул барыбер башкаларның нәрсә сөйләгәннәрен аңламый. Җитмәсә бит әле, мәдрәсә тирәсендә булгач, алар кебек намаз укырга, күз буяу өчен булса да, динен тотарга кирәк. Совет елларында мондый кадрлар күпләп әзерләндемени? Берәм-сәрән әзерләнсә дә, шымчылык итү өчен алар гарәп илләренә китеп бардылар, мөфтиләр итеп куелдылар, зур мәчетләргә имамнар итеп керттеләр. Бүген исә ул мәчет-мәдрәсәләр шулхәтле күбәйде, кайда, кемне кертеп өлгерергә дә белгән юк. Һәм менә монда, борын төбендә, Фабарисовның гөманлавы буенча, шушы мәдрәсәләрдә Аллаһ сугышчылары әзерләп ятсыннар инде! Алар бит шәһәрдәге, авыллардагы башка мөселманнар бе-

лән дә аралашып торалар, боларга ияреп, тагы күпме яшьләр Россиягә каршы кулына корал алгандыр — Мәскәү моның тәгаен шулай икәнен ачык белсә, иң беренче эш итеп бу мөҗәһитләрне түгел, ә менә Фабарисовларның муенын борачак, Татарстан җитәкчеләрен астырачак! «Без белмәдек» дип әйтергә беркемнең дә хакы юк, алар монда белү өчен куелган. Россиягә килгән куркынычны тамырыннан юк итү өчен куелган. Татар Россиягә каршы чыгамы, чеченмы, мөселманмы — аларның урыны йә төрмәдә, йә кабердә булырга тиеш, Фабарисов әнә шулай уйлый иде. Ничек итеп Фабарисов хәтле Фабарисовны, карт төлкене, органнарда эшләп чәче коелган бер шымчыны шундый оста итеп алдый, төп башына утырта алдылар соң бу татар егетләре? Кем булышкан аларга, кем?!

Фабарисов мәдрәсәгә әнә шулай ярсып, кайнап барып керде. Дөрес, аның биредә элегрәк елларда да булганы бар иде. Аны биредә елмаеп каршы алалар иде, чәйләр эчертеп, яхшылап озаталар иде. Башларын иеп кенә мәдрәсә буйлап оекчан йөргән, күп вакытларын намазда уздырган бу ябык татар шәкертләрен кызганып та куя иде Фабарисов. Аларның яшьтәшләре кырда туп тибә, җырлый-бии, дөбердәтеп дөнья куа, ә болар ачлы-туклы Коръән өйрәнә. Кемгә кирәк болар, ничек яшәрләр бу бичаралар?

Соңгы вакытларда Фабарисов, милли хәрәкәт, татар мәктәпләрен күзәтү белән мавыгып китеп, мәдрәсәләрне бөтенләй күздән ычкындырган иде. Ә алар әнә тик ятмаган булып чыктылар. Алардан, бары тик алардан күрә иде Фабарисов тирә-юньгә саф исламның таралуын, көчле рухлы, үлемнән курыкмый торган яшьләр әзерләнүен, Россиягә төп куркыныч янавын. Көчәеп китсәләр, Татарстанга чын бәйсезлекне дә нәкъ менә шушы яшьләр алып бирергә мөмкин иде. «Болар инде милләтчеләр кебек байрак болгап, кәгазь язып кына йөрмәячәкләр, — дип уйлады Фабарисов шомланып. — Болар милләтне, динне, Татарстанны корал белән саклаячаклар! Болар бәйсезлеккә дә, дингә дә уен итеп карамый, болар шушы изге максатлары өчен хәтта үз тормышларын да кызганмыйлар бит! Димәк, бу мәдрәсәләрне яптырырга йә бу фанатикларның үзләрен юкка чыгарырга кирәк». Фабарисов мәдрәсәгә әнә шундый дәһшәтле уйлар белән килеп керде. Бу — ике чечен сугышы арасындагы бер хәвефле чор, 1997 елның көзе иде...

Ректор ишеге төбендәге өстәлдә Мәрьямбануның эшләп утыруын күргәч, Фабарисов артка авып китә язды. Менә кая килеп оялаган икән бу милләтче хатын?! Хәтта Фабари-

совны да саташтыра язган, горур, башбирмәс чая хатын! Заманында йөзеннән нур чәчеп торган, бөтен килеш-килбәте затлы патшабикәләрне хәтерләткән Мәрьямбану бүген башына яулык бәйләп, әллә нинди озын күлмәкләр киеп, мәдрәсәдә утыра! Бу — Фабарисов белгән, Фабарисов теләгән, Фабарисов хыялланган хатын түгел иде. Әйтерсең лә Мәрьямбану яулык-чапанга гына чорналмаган, ә тимер калкан кигән... Шул ук горур кыяфәт, шул ук акыллы караш, шул ук үз-үзенә ышаныч. Министр урынында утырамыни! Югыйсә бу хатын барысын да югалтты бит инде — кырыенда тау бөркете кебек ире дә юк, дәрәҗәле эше, исеме дә юк. Ә үзен ничек тота!

— Җайлы урнашкансыз, Мәрьям ханым, — дип әйтүдән артык узалмады Фабарисов. — Эзләп табарлык та түгел...

— Менә... тапкансыз бит.

Күренеп тора, Мәрьямбануның Хәррис белән бәхәскә, сүзгә керәсе килми иде. Фабарисов та югалыбрак калды. Фетнәчеләр эзләп килде — үзенең күңел ярасына тап булды. Хәер, Фабарисов белгән, Фабарисовны саташтырган хатын юк иде инде, ул үлгән иде. Аның урынын мәрмәр таш сын алган иде. Мәрьямбануны бу кыяфәтендә Фабарисовның беренче күрүе иде. Аның бу килеш-килбәте Фабарисовны куркытты, читкә этәрде. Нәрсә булган Мәрьямбануга шушы юлга кереп китәрлек? Әллә Фабарисов та теге вакытта арттырып җибәрдеме, гаиләсенә теге сихерче хатынны кертеп, юкка гына Тимербулат белән арасын боздырдымы? Ул бит аны Мәрьямбану үзенеке булсын өченгә эшләгән иде. Ялгызлыкка түзә алмыйча, ханбикәләргә тиң бу гүзәл хатын, бу зирәк хатын Хәррискә карар, Хәрриснеке булыр дип өмет иткән иде... Ә ул әнә Тимербулат белән дә калмаган, Хәрриснеке дә булмаган — дингә киткән. Горур башына мәңгелеккә яулык ябынган, сылу гәүдәсен чапан-хиҗаб астына яшергән, бу азгын дөньядан, бу гөнаһлы назлардан үз ихтыяры белән киткән, үткәннәргә капкаларын япкан... Мәрьямбануның тормышында, күңел дөньясында Фабарисовка элек тә урын юк иде, хәзер исә бу хатынга якын да килерлек түгел. Әйтерсең лә аны яулык-хиҗабы гына түгел, фәрештәләр гаскәре саклап тора! Фабарисов белән бу хатын арасында таштан пәрдә барлыкка килгән иде... Азгынлыкка каршы үз күңелендә таш дивар кора алган бу мөселман хатыны Фабарисовның үзенә дә кирәк түгел иде инде...

— Ректорыгыз белән сөйләшергә иде, Мәрьям ханым, — диде ул, төп эшенә күчәргә исәпләп.

Хәзер аңа Мәрьямбанудан бары тик мәгълүмат кына ки-

рәк иде. Әмма бу хатынның артыгын ычкындырмаячагын да бик яхшы белә иде Фабарисов.

— Ул бүген өйдә юк, — диде Мәрьямбану, чыннан да бик җәелеп тормыйча. — Мәдрәсәгә кагылышлы сорауларыгызны миңа бирә аласыз, мин ректорның хуҗалык эшләре буенча ярдәмчесе.

«Завхоз, димәк, — дип уйлады Фабарисов, ирен читләре белән елмаеп. — Күренекле биолог, дәреслекләр авторы, данлыклы милләтче — мәдрәсәдә завхоз?» Әмма шул мизгелдә үк Фабарисов бу уйларыннан кире кайтты. Юк, завхоз булып кына утыра торган хатын түгел бу, Фабарисов сизеп тора — мәдрәсәдәге төп эшне, идеологияне шушы милләтче хатын алып барырга тиеш. Ничек элегрәк шушы хакта уйламады соң Фабарисов? Бу хатын бөтенләй икенче яктан башын әйләндерде, зиһенен чуалтты, сизгерлеген киметте шул. Ә чын милләтче кайда да милләтче булып кала бит — мәдрәсәгә киләме ул, мәктәпләргәме, дәүләт органнарына кереп утырамы — барыбер үзенекен сукалый — Россиягә каршы өзлексез эш алып бара. Әле бу мәдрәсәдә дин әһелләре, шәкертләр генә булса, Фабарисов аларны ничек почмакка терәсен белер иде, кыймылдый да алмаслар иде. Ә бу хатын белән авыр булачак аңа, ул үзе дә органнарның һәр адымын эшләмәс борын белеп тора, андагы сизгерлек һәм акыл бөтен КГБны алыштырырлык, төп башына утыртырлык. Ул хәзер бу шәкертләрне хөкем кулына бирмәс өчен мең төрле юлын эзләячәк, мең төрле юлын табачак. Кирәк икән, аларның үзләрен үк ачлыкка җыеп чыгачак, кирәк икән, чит илләрнең хокук саклау оешмаларына мөрәҗәгать итәчәк, кирәк икән, Россиянең үзе белән судлашуларга кадәр барып җитәчәк, әмма үзенекен итәчәк! Дингә мондый укыган, элек зур урыннарда эшләгән кешеләрнең килүе органнар өчен дә, Россиянең үзе өчен дә куркыныч тудыра иде, чөнки бу мөселманнарга ислам дине мәет күмү өчен генә түгел, дөньяда яшәү өчен кирәк иде...

— Бераз мәдрәсә белән танышып чыгарга иде, Мәрьям ханым, — диде Фабарисов, үзенең уйларын яшерергә тырышып. — Нindирәк китаплар укыйлар икән шәкертләрегез, уку программасында нинди дәресләр бар?

Бу хатыннан «Шәкертләрегез, укып бетергәч, кая китә, чечен сугышында катнашучылар арасында сезнекеләр дә юк идеме?» дип сорап булмый бит инде. Ул аны белсә дә әйтмәячәк, нәрсәне яшерергә, нәрсәне әйтергә кирәген бик яхшы белә бу хатын. Әле үзе белгәннәрне башкаларга да өйрәтәдер, шул гомер берни сиздерми мөҗәһитләр әзерләп ятмас-

лар иде. Әмма утыз ел органнарда эшләгән Фабарисов әле ул! Сез акыл белән барсагыз, ул мәкер белән барыр, әмма барыбер эзләгәнен табар, үзенчә эшләр, соңгы нәтиҗә аның файдасына булыр.

Фабарисовны китапханәгә Мәрьямбану үзе озата килде. Киштәләрдән дәһшәт белән карап торган калын-калын китапларны күргәч, Фабарисовның тәне калтырап куйды. Әйтерсең лә бу билгесез китаплардан Фабарисовка куркыныч яный иде. Ул бу дини китаплар мәгарәсендә үзен телсез, чукрак, сукыр кеше кебек хис итте — китаплар барысы да гарәпчә иде һәм аларда нәрсә язылганын Фабарисов аңламый иде. Берничә китапны кулына алып әйләндереп караса да, бу серле хәрефләр аңа үзләренең хикмәтләрен ачмадылар, киресенчә, аңламавы сәбәпле, тагы да шомлы һәм куркыныч булып күренделәр. Бу күн тышлы китаплар үзләренең авырлыклары белән Фабарисовның кулларын гына түгел, каралган җанын һәм картайган тәнен дә бастылар. Калтыранган куллары белән Фабарисов аларны тизрәк үз урыннарына тыгып куярга ашыкты. «Казаннан кеше чакыртып, барысын да укытырга, белергә кирәк, — дип уйлады ул. — Нинди агу таратып яталар икән алар шәһәргә? Кайлардан җыеп бетергәннәр аларны? Теге еллар булса, Фабарисов әллә кайчан аларны җыеп алып, утка аттырган булыр иде. Нинди заманнар җитте бит! Борын төбеңдә сиңа каршы укытып ятсыннар инде!»

— Боларны аңлаучы кеше бармы соң монда? — дип сораган булды ул, эчтән ярсып калтыравын Мәрьямбануга сиздерәсе килмичә.

— Болар — Коръән тәфсирләре, ягъни Коръән аятьләренә тулы аңлатмалар, — дип җавап бирде Мәрьямбану да туры сорауга туры җавап бирмичә. — Теләсәгез, мин үзем дә сезгә укып-аңлатып бирә алам.

Фабарисов, күзләрен шарландырып, Мәрьямбануга текәлде. Ул диндә шушы китапларны укып-аңларлык хәлгә килгәнме?! Эчендәге нинди дер кара көч Фабарисовка моннан тизрәк чыгып китәргә, бу китаплардан, әүлия кыяфәтле бу хатыннан ераграк качарга чакыра иде. Ректорыгыз кайткач керермен алайса, дип, Фабарисов тизрәк чыгу ягына борылды. Ул бу хатынның тәэсиреннән, көченнән курка иде, Фабарисов аңа мәкер белән килсә, Мәрьямбану ул мәкерне иман көче белән җиңәргә әзер иде. Бу хатын белән ачыктан-ачык яу кырына чыгарга ярамый иде, Фабарисов барыбер җиңелергә һәм чигенергә мәҗбүр булачак иде.

Фабарисов бу мәдрәсәгә әйләнгеч, яшерен юллар белән

үтеп керергә уйлады. Бу юлларда үзенең бөтен көчен, тәҗрибәсен һәм осталыгын мәдрәсә белән бәйле мәсьәләләрне ачыклауга юнәлтте ул. Дөрес, боларның барысын да Казан яки Мәскәү әйткән өчен генә эшләмәде Фабарисов, карт чекист буларак, мәдрәсәдән чын шикләнү белән шикләнеп, бу күзәтүләренең, бу эшенең кайчан булса да бер кирәк булачагына ышанып хәрәкәт итте ул. Һәм Фабарисов шуны аңлады — бу мәдрәсә патша заманында алып барылган идеологиягә дә, коммунистлар өйрәтүенә дә, милләтчеләр чакыруына да, Россия законнарына да туры килми, алар юлыннан бармый, аларча яшәргә өндәми иде. Бу мәдрәсә бары тик Аллаһы Тәгалә кушканча, Коръәндә язылганча гына яшәргә өйрәтә. Әмма татар милләтенә, Татарстан һәм Россия җитәкчеләренә болай яшәү файдалымы — мәдрәсәдә анысына игътибар итмиләр, ахры. Алар бары тик Аллаһка гына буйсынырга чакыралар һәм үзләре дә шулай яшиләр. Ә законнар, ә җитәкчелек, ә илдә урнашкан тәртип?! Хәзер шуларның барысын да Аллаһ кушканча үзгәртергәме? Кемгә кирәк ул? Халык сугышып бетәчәк, әмма үз тәртипләреннән, үз гореф-гадәтләреннән, дин чикли торган үз рәхәтлекләреннән аерылмаячак. Дәүләт тә моңа ирек бирмәячәк, чөнки дәүләт өчен халыкның Аллаһка түгел, ә дәүләт чыгарган законнарга, дәүләт урнаштырган тәртипләргә буйсынып яшәве хәерлерәк. Димәк, шушы бер төркем мөселманнар, җәмгыятьнең үзенчә көйләнгән тынычлыгын бозып, ыгы-зыгы китереп чыгарырга мөмкиннәр? Ә аларга иярүчеләр күбәеп китсә? Вакыт та алар файдасына эшли бит — илне ашап килгән СПИДтан, наркоманиядән куркып, эчкечелектән болай гына котыла алмасын белеп, күпләр хәзер ислам дине кочагына килеп ава. Гаетләрдә халыкның күплеге шомлы бер хәл булып күренә башлады Фабарисовка. Әгәр аларның барысы да дингә килсә? Ярый да әле хәзер Гаеттән кайталар да кичен утырып эчәләр, дин дип тилереп йөрмиләр. Уразаларын аракы белән ачып тотучы татарлар бар. Болардан дәүләткә бер куркыныч та юк, эчкәне — эчеп үләр, дәүләт өчен калганы да җитәр. Ә менә чын-чынлап дингә килеп, Коръән буенча гына яши башласалар? Ул халыкка Россия законнары, җитәкчелек урнаштырган тәртипләр ошамый башласа? Димәк, татар арасында таралып өлгермәсен өчен, гарәпләр алып килгән бу идеологияне тамырыннан юк итәргә, ком чүлләреннән килгән ул китапларны бетерергә, бу мәдрәсәдә укучыларны — надан, мөселманнарны вәхши һәм явыз итеп күрсәтергә кирәк булачак? Тора-бара Мәскәү үзе дә шушы хакыйкатькә барып җитәчәк, әмма Фаба-

рисов аны менә монда — урында — барысыннан да тизрәк аңлады, мөселманнардан килгән бу хәвефле көчне барысыннан да алданрак тойды. Һәм алга таба бөтен эшчәнлеген аларга каршы алып бара башлады.

Фабарисовның бәхетенә, Мәскәүдә дә бу хәлне тиз аңладылар, ислам диненең көчәеп китүен күреп, үзләре өчен килеп туган бу куркынычка дөрес бәя бирделәр. Чөнки инде Кавказда, хәтта Чечня булып Чечняда да, милли бәйсезлек идеясен бер читкә куеп, дини бәйсезлек байрагы тирәсенә туплана башлаганнар иде. Әгәр шушы хәл Идел буенда, Уралда да кузгалса, Фабарисовның мәчет-мәдрәсәләр тирәсендә бүген алып барган эшчәнлеге бик нык кирәк булачак иде.

Иң беренче эш итеп, Фабарисов мәдрәсәгә үзенең кешеләрен урнаштырырга тырышты. Аның эш алымы шулай иде — барысын да үзең күзәтеп бетерә алмыйсың, шуңа күрә бөтен җирдә синең кешеләрең булырга тиеш. Мөселманнар янында — мөселман кыяфәтендә, милләтчеләр арасында — милләтче булып, театрларда, газет-журнал тирәләрендә һәрберсендә хәбәр биреп торырлык кешеләр булырга тиеш. Мәчетләр тирәсендә бу эшне эшләү шактый ук җайлы булса да, мәдрәсәләрдә, бигрәк тә гарәпләр укыткан менә бу мәдрәсәдә, Фабарисовка үз кешеләрен урнаштыру шактый авыр булды. Иң башта ул, төрле хәйлә-мәкер белән, мәдрәсәдән гарәп укытучыларын кудыруга ирешге. Аннан зур гыйлемле, диндә бик ихлас һәм тәкъва булган ректорны китәргә мәҗбүр итте. Болардан соң хуҗалык эшләренә, аш-су тирәсенә үз кешеләрен урнаштырып карады Фабарисов, әмма тел белмәгән, укыту процессына катнаша алмаган бу кешеләрдән әллә ни файда күрә алмады. Фабарисовның хыялы — шәкертләр арасына үз кешеләрен кертеп укыту иде. Шулар аша мәдрәсәдәниләр эшләнгәнен белеп тору, кирәк булса, шушы кешеләр аша мәдрәсәнең дәрәҗәсен төшерә торган гамәлләр, фетнәләр, провокацияләр оештыру иде. Әмма Фабарисов урнаштырган кешеләр мәдрәсәдә озак түзә алмадылар, ярты ел, бер ел укыган кыяфәтле булып йөрделәр дә китеп бардылар. Чөнки мәдрәсәдәге кырыс тәртипкә, баш күтәрмичә дин, гарәп теле өйрәнүгә, көне-төне укыган намазларга түзә алмадылар алар, мөселман булып уйнап булса да, уйнап кына гамәл кылып булмаганлыгын яхшы аңладылар.

Фабарисовка мәдрәсә турында Мәскәүдән дә гел тамызып, кыздырып тордылар, хәзер инде аның үзенең һәр адымын күзәтәләр, тикшереп торалар иде. Шуңа күрә Фабарисов та тиресеннән чыгарлык булып тырышты, мәдрәсә өсте-

нә бәла-казаларны, борчу-проблемаларны өеп кенә торды. Шәкертләрне наркоманлыкта гаепләү өчен, мәдрәсәгә укырга берничә наркоманны кертеп карады. Әмма бу шикле егетләрне шәкертләр бик тиз сизеп алдылар, шул көнендә үк мәдрәсәдән чыгарып та җибәрделәр. Этләр белән милиция килеп җиткәндә, инде ул наркоманнарның монда эзе дә калмаган иде.

Үз кешеләре аша Фабарисов соңыннан шуны белде — Мәрьямбану милиция килгәнче үк наркоман егетләр яшереп киткән порошок-шприцларны табып алып, утка ташлаттырган. Бу эше барып чыкмагач, Фабарисов мәдрәсәгә зиначы кызларны урнаштырып карады. Исәбе — техникумдагы кебек, мәдрәсәдә дә СПИД белән авыручыларны табу, фаш итү иде. Әгәр бу планы барып чыкса, Фабарисов берьюлы ике куянны ата иде — мөселман кызларын йогышлы авырулар таратуда гаепли һәм шуңа нигезләнеп, мәдрәсәне яптыруга ирешә. Әмма Фабарисовның кызлары арттырып җибәргән булып чыктылар, пәрәнҗәләр ябынган хәлдә, сабантуйда сыра эчеп йөргәннәр. Шул сабантуй мәйданыннан аларны яңадан мәдрәсәгә кертмәделәр. Мәрьямбану аларга хәтта шәһәрдән үк чыгып китәргә боерган. Фабарисов соңыннан күпме генә эзләп караса да, аларны башка таба алмады.

Инде бу этлекләре барып чыкмагач, Фабарисов мәдрәсәне икътисади яктан буа башлады — җир өчен, су өчен, ут өчен, яшәгән, сулаган өчен мәдрәсәгә миллионлаган суммада салымнар китереп салдылар. Дини уку йортларына хәтта законда да ул хәтле салымнар каралмаган иде. Мәдрәсә җитәкчеләре, ишек саен йөреп, моны исбат иткән арада, салымнарны түләмәгән өчен ут һәм суларын өзеп куйдылар, шәкертләр шәм яктысында, ачлы-туклы укуларын дәвам иттеләр. Бу мәсьәлә буенча да Мәрьямбану Мәскәүгә үзе барды, судлар аша үзләренең хаклы икәнлеген исбатлады. Ул арада мәдрәсәгә Казаннан зур-зур комиссияләр килә башлады, алар һәр дәреслекне, шәкертләр укый торган һәр китапны актардылар, иснәнделәр, эзләделәр, бернәрсә таба алмагач, мәдрәсәдә дин дәресләренең артык күп укытылуын гаепләп чыктылар, программага логика, философия, дидактика кебек дингә каршы фәннәр кертеп тутырдылар. Боларны укытырга да Мәрьямбану мөгаллимәләрне үзе тапты, берничә айдан инде алар дингә кереп китеп, фәлсәфә урынына дин сөйли башладылар... Мәдрәсә ял көннәрне, хәтта төннәрен дә укытуга күчте, төп халык — яшьләр һәм хатын-кызлар иде. Өсләренә килгән афәттән шушы рәвешле котылырга теләгәндәй, та-

тарлар йөзәрләп, меңәрләп Коръән өйрәнергә утырдылар, соңгы көчләрен, иманнарын туплап, Аллаһ юлына аяк бастылар. Өйрәнгән берсе халык арасына — авылларга һәм шәһәрләргә тарала барды, алар үзләре генә түгел, милләтне дә динсезлектән, әхлаксызлыктан коткарырга тиешләр иде. Бигрәк тә татар хатын-кызлары дин юлында үзләренең искиткеч тырышлыкларын күрсәттеләр, халыкка дин сабагы бирүдә алар өчен көн дә, төн дә юк иде. Алар бөтен гаиләләрен, күрше-күләннәрен шушы юлга тарттылар, күңелләрен каплап барган караңгылыктан, сазлыктан тартып алдылар. Болар барысы да Мәрьямбану шәкертләре, аның тарафдарлары иде. Фабарисовка, көферлеккә каршы, хәзер мең Мәрьямбану, мең мөселман хатыны көрәшә иде... Фабарисов мәдрәсәгә һәм Мәрьямбануга һөҗүмен вакытлыча туктатып торырга булды, чөнки Мәскәү аның алдына тагы да мөһимрәк максатлар куйган иде.

Теге елларда Фабарисов кушуы буенча ярты ел, бер ел мәдрәсәдә укып чыккан шәкертләрне тулы көчләренә файдаланыр вакыт җитте. Россия Чечняга яңадан сугыш башларга җыена, һәм бу Фабарисов «мөселманнары» анда барып, чеченнарның ышанычына кереп, Россиягә кирәкле бөтен мәгълүматларны биреп барырга тиешләр иде. Фабарисов һәм аның шәкертләре хәзер Россия өчен иң кирәкле, иң кыйммәтле кешеләргә әйләнделәр. Пәрәвезне бик оста итеп, хәтта Мәскәүләрнең үзләрен дә көнләштерерлек итеп үрде шул Фабарисов. Бу мәкерле эшен дә бит инде ул әнә кайчан башлаган иде! Һәм Фабарисовның даны, аның эше әнә кайларга барып җитте, нинди бөек максатларга хезмәт итә — Россиянең бөтенлеген саклауга! Аның белән Мәскәүнең иң зур генераллары хәбәрләшә башлады, киңәшләрен биреп, төзәткәләп тордылар. Фабарисов үзенең дәүләткүләм эшләрдә катнашуын аңлады, картлык көнендә өстенә ишелеп килгән мондый танылу, дан-дәрәҗәләр аны тагы да канатландырып, үсендереп җибәрде. Бу юлда аны нindидер Мәрьямбанулар гына түгел, Ходай үзе дә туктата алмас кебек тоелды...

Фабарисовның эченә шайтан кереп утырган иде, ул инде үзе дә адәми шайтанга әйләнеп, җир йөзендәге барлык изгелеккә, яхшылыкка, илаһи нурга каршы көрәшкә чыккан иде. Әмма бу көрәшнең инде ахыры якынлашып килүен, үзенең бик тиздән терелəй утта янасын Фабарисов әле белми иде...

* * *

Хәйдәрне дә Фабарисов үзе эзләп тапты, шушы бөек максатларны тормышка ашыру өчен әзерләде, үстерде. Дөресрәге, Хәйдәрнең әнисе үзе Фабарисовка чыкты. Бу хәл ике чечен сугышы арасында булды. Фабарисовның шәһәр советы депутаты буларак халыкны кабул иткән көне иде. Йөзе арыган, таушалган, өстенә теге заманнардан калган соңгы киемнәрен кигән бу хатынга Фабарисов, бәлки, игътибар да итмәгән булыр иде, кәгазьләрен ничек күтәреп керсә, шулай чыгып та китәр иде. Әмма ире турында сөйләргә кергән хатын елый-елый улына күчкәч, Фабарисов игътибар беләнрәк тыңлый башлады. Хатынның ире моннан берничә ел элек кеше таптатып, төрмәгә эләккән булган, бу хатын хәзер, бүлмәдән бүлмәгә йөреп, иренең гаепсез булуын исбатларга тырыша. Җитмәсә, малаена ишегалдындагы наркоманнар яный икән, көн саен акча таптыралар, кыйныйлар, ди. Янында атасы булмагач, барысы да басымчак итә икән. Хатын әйткәнчә, укырга кертергә дә акчалары юк икән, укуы да ни татарча, ни урысча, ди.

— Нигә алай — ни татарча, ни урысча соң? — дип сорады Фабарисов, малай белән ныграк кызыксынып.

— Татар гимназиясен бетерде. Башта урыс мәктәбендә укыган иде, аннан күрше Мәрьямбануның малае белән татар гимназиясенә йөри башлады. Шулай итеп, ике арада калды...

«Мәрьямбану малае? Димәк, бу хатын алар белән бер йортта тора?»

— Мәрьямбану, дидегез, бу — элеккеге педтехникум директоры турында әйтмисездер бит?

— Шулар инде, шулар... Аннан чыгардылар бит аны. Хәзер мәдрәсәдә эшли бугай. Малае да шунда укып йөри, ди. Алар югалмаслар, менә безгә генә кайда да урын юк...

— Ә нигә сез дә малаегызны мәдрәсәгә урнаштырмадыгыз?

Хатын Фабарисовка гаҗәпләнеп карап торды. Мондый зур урында эшли торган кеше авызыннан бу сүзләрне ишетү сәер иде аңа.

— Соң, ул бит урнаштырып кына укый торган урын түгел. Анда бит намаз укырга кирәк, дин тотарга... Мулла булу рәвеше бөтенләй юк анда.

— Мәдрәсәне бетергән һәр кешегә мулла булырга димәгән... Сез малаегызны минем янга җибәрегез әле, үзем сөйләшеп карармын.

Хатын каушап ук китте. Нигә истә-оста юк урында, аның

улын мәдрәсәгә кодалап утыра әле бу кеше? Жәлләп әйтә дияр идең, хәзер кешене кеше жәлләми. «Минем янга җибәр» ди бит. Туган түгел, ни түгел, берәр бай баласы, начальство туган-тумачасы түгел... Ни ята икән моның төбендә?

— Ирегез турында кәгазьләрне калдырыгыз. Мин, һичшиксез, ярдәм итәргә тырышырмын. Ул төрмәләрдә күбрәк гаепсез кешеләр утыра хәзер...

Монысы инде бөтенләй кеше ышанмаслык хәл иде. Хатын, саубуллашырга да онытып, депутат бүлмәсеннән чыгып китте. Әлбәттә, аның малае Фабарисов янына килмәде. Әмма Фабарисов бу сөйләшүне онытмаган иде. Ул гына да түгел, бу урам малаен үз янына китерерлек чараларын да күргән иде инде ул...

Хәйдәрне, кесәсеннән наркотиклар табып, кулга алдылар...

Бераздан ана, канлы яшьләрен түгеп, тагы Фабарисов аягына килеп егылды:

— Баламның гаебе юк, — диде ул, үкси-үкси елап. — Кесәсенә тыкканнар... Шунда ук килеп кулга да алганнар. Ул бала наркотикның да, аракының да нәрсә икәнен белми... Алла хакы өчен, ярдәм итегез...

— Теге вакытта юкка минем янга җибәрмәдегез. Мәдрәсә мәсьәләсендә, дим...

— Әйтеп карадым. «Әни, мин динне бөтенләй белмим бит» диде. Белүен дә белми инде. Үзем дә белмим, атасы да белми иде, укыган кеше нәселебездә дә булмады... Болай булып бетәсен белгән булсам, үзем җитәкләп алып килгән булыр идем. Төрмәдә утырганчы, мәдрәсәдә укуы яхшырак булыр иде...

— Әле соң түгел, — диде Фабарисов сүзне һаман шул тирәдә куертып. — Улыгыз белән дә, мәдрәсә белән дә үзем сөйләшермен.

— Ә милиция белән? Ул бит инде алар кулында!

— Алар белән дә үзем сөйләшермен. Ул наркотикларда улыгызның бармак эзләре юк бит, гаебен исбатлау да авыр булачак. — Артыгын ычкындыруын аңлап, тизрәк өстәп куйды. — Әлбәттә, теләсәләр, гаебен дә табарлар, бер ун елга утыртып та куярлар... Ну, бер татар баласын карап торып харап иттереп булмый бит инде...

Бәхетсез анага бу мизгелләрдә Фабарисов дөньяның иң изге кешесе, әүлия, фәрештә булып тоелды. Әмма каршында иң мәкерле адәми шайтан утыруын, бу кешегә улының җаны кирәк икәнен һәм шуңа ирешмичә аның мәңге тынычланмаячагын бу бәхетсез ана аңламый иде шул әле. Аңламый иде...

***Йорт ыңгырашып куйган кебек булды...***

***Аның тынычлыгы бозылды. Бәндәләрнең җир күтәрмәслек эшләрен Йорт күтәрде, явызлыкларын һәм бозыклыкларын таш куенына яшерергә мәҗбүр булды. Бу Йорт барысын да күрде. Бу Йорт арыды. Йорт, авыр сулап, тетрәнеп куйды. Таш диварларның ыңгырашуы Йорттагы барлык җан ияләрен, бөҗәк-хәшәрәтләрне хәрәкәткә китерде, алар Йортны ташлап кача башладылар. Йортка афәт килә иде. Җан ияләре моны күрде, сизде, әмма кешеләр сизмәделәр... Йорт, әнә шул тере мәетләрне таш куенына алып, соңгы гөнаһлы төненә, Җир тирәли соңгы әйләнешенә кереп бара. Йорт ияләре — җеннәр һәм фәрештәләр дә инде аннан качты, өсләренә нинди зур бәла килгәнен, җәза төшкәнен алар да аңладылар, алар да күрделәр... Тик адәм баласы гына берни күрмәде, берни сизмәде. Ул, дөньяга мәңгегә килгән кебек, шашынып күңел ачты, мал җыйды, зина кылды, гөнаһын арттырды...***

***Үзенең соңгы төне икәнен Йорт булып Йорт, таш булып таш аңлады, адәм баласы гына белми һәм белергә дә теләми иде...***

Фабарисов Мәскәүдән ашыгыч хәбәр алды — аңа кичекмәстән Хәйдәр янына барырга куштылар. Мәскәү бик ачулы һәм канәгать түгел иде. Әле яңа гына очынып йөргән, бөтен җаны-тәне белән тантана иткән Фабарисов югалып, бетеренеп калды. Нәрсә булган? Барысы да язып куйганча ялт итеп бара иде бит!

— Кемнәрне җибәреп ятасыз сез анда?! — Мәскәү өстәл төеп кычкыра иде. — Җибәргән кешеләрегез киресен сөйләп утыралар! Сез кемгә эшләп ятасыз анда — Мәскәүгәме, әллә чеченнаргамы?!

Фабарисовның күсәк белән биленә китереп суккан кебек булды. Бу оешмада алай сөйләшү юк иде. Бу оешмада гомер буе бер-берләрен сынап белгән, ышанычлы кешеләр утыра иде. Һәм менә сиңа мә! «Кемгә эшлисез? Кемнәрне җибәреп ятасыз?» Фабарисов белән беркайчан да мәскәүләрнең болай сөйләшкәне юк иде. Кичекмәстән Хәйдәр янына барырга куштылар һәм, Мәскәүдән хәбәр килмичә, ул егет яныннан китмәскә боердылар. Димәк, Мәскәүнең шулай җикеренүе Хәйдәр белән бәйләнгән, Хәйдәр нәрсәдер майтарган монда, шуның ачуын хәзер Фабарисовтан алалар...

Хәйдәрнең көндез телевизордан үз-үзен тотышы Фабарисовка да ошап бетмәде. Өздереп шул чечен бандитларына каршы барысын да сөйләп бирәсе урынга, башын читкә бо-

рып, тик утырды. Кулга эләккән чеченнар үзләре дә әнә боевикларны, ваххабиларны эт итеп сүгәләр, ә бу, махсус шунда җибәрелә торып, безнең кеше була торып, Мәскәүнең күңеле булырлык ник бер сүз әйтсен! Югыйсә ул бит барысын да күргән — татар егетләрен ничек атканнарын да, чеченнарның явызлыкларын да... Соң, сөйлә инде шулар турында авыз тутырып, Мәскәүне сөендерерлек итеп! Фабарисовның да күңеле булыр иде, ни дисәң дә — аның кадры бит! Юк! Әле ул гынамы — Мәскәүдә үзенә карата шик уяткан. Әле моңа кадәр Фабарисов җибәргән кадрларга йөз процент ышаналар иде, ул Чечняга үзенең күп егетләрен җибәрде, шактый мәгълүмат ташыдылар алар Мәскәү өчен, күп файда китерделәр. Һәм менә — ялгыш! Хәрбиләр теле белән әйткәндә — осечка! Ул, әлбәттә, Хәйдәрдән барысын да әйттерер, бугазына басып булса да сөйләтер. Бәлки, аны Мәскәүдә дөрес аңламаганнардыр? Ул бозау малай берьюлы ике якка эшли аламы соң инде? Әле үзенең бер якка — Мәскәү ягына, ФСБга эшләвен дә аңлап бетермәгәндер. Ул бит үзен Чечняга Фабарисов җибәргәнгә киттем дип белә, Фабарисовка ярар өчен генә тырыша... Үзенең Чечняга барып-кайтып йөрүләренең төбендә нәрсә ятканын ул малай һаман аңламагандыр әле...

Мәскәү шулай йөзгә бәрерлек булгач, димәк, кайдадыр ялгыш киткән инде. Кайда ялгышты икән соң Фабарисов? Хәйдәрне дә, аның әмере буенча Чечняга китүче башка татар егетләрен дә ул еллар буе берәмтекләп җыйган, җентекләп әзерләгән иде бит! Бу — шулхәтле нечкә үрелгән бөек һәм җиңелмәс план иде, хәтта Мәскәү үзе дә шаккаткан иде. Фабарисов Россиянең Чечняга каршы кайчан да булса бер сугыш башлыйсын бик яхшы белде һәм үзе дә бу сугышка берничә ел алдан әзерләнә башлады. Чечняда сугыш кузгалса, татар егетләренең тагы Чечняны яклап шунда китәсен бик яхшы белде ул. Теге юлы татарларның чеченнар ягыннан сугышуын Мәскәү теш кысып үткәреп җибәрсә дә, бу юлы хәл башкача булачак — бу юлы Мәскәү кичермәячәк. Чечен сугышына барып кергән мөселман-татарларга тозакны шундый итеп корырга кирәк иде ки, чеченнар үзләре аларны тотып юк итәрлек булсын! Ягъни моннан Чечняга китүче татар егетләре арасына Фабарисов кешеләре дә керергә тиеш. Әлбәттә, алар да мөселман булып йөрергә, Хаттаб лагерьларында укырга, кирәк икән, сугышта да катнашырга тиешләр. Ләкин эшләвен аларга түгел, Мәскәүгә эшләргә тиеш алар. Бөтен мәгълүматны шунда җибәреп барырга, җай чыкса, кыр командирларын үтерергә, тотыла кал-

салар, чын мөселман-татар егетләрен «Болар КГБга эшлиләр» дип күрсәтергә тиешләр. Хәтта тотылмаган очракта да, моннан киткән мөселманнар турында шик уятырга, аларга каршы чеченнарны котыртырга. Аннан тикшереп кара син — бу татарларның кайсы КГБга эшләгән дә, кайсы Аллаһка эшләгән! Фабарисов чеченнарның холкын белә — барлык татарларны да тотып атачаклар алар. Әлбәттә, бу — бик хәвефле юл, әмма татарларны чеченнарга ярдәм итүдән бүтән тыяр юл юк. Үз егетләре күрәләтә харап булмасыннар өчен, аларны еш кына алмаштырып торырга туры киләчәк. Кайберләре, бәлки, анда берни эшли дә алмас, әмма бу очракка да Фабарисовның планы әзер — ул аларны башта «мөселман» итеп чеченнар арасында йөртер, аннан ОМОН отрядларында кулларына корал тоттырып, чеченнарга каршы җибәрер. Чечня — кечкенә җир, татарлар турында бу хәбәр тау араларында тиз таралачак. Һәм хәтта шушы хәбәр дә моннан киткән чын мөселманнарга, татарларга каршы эшләячәк, аларның һәрберсенә шикләнеп карый башлаячаклар.

Әнә шулай итеп, әле сугыш башланырга берничә ел кала, Фабарисов үзенең шушы пәрәвезен үрә башлады, бөтен гомерлек тәҗрибәсен җыеп, шушы максатка барды, бөек җиңү өчен эшләде. Татарларның башларына баса-баса, аларны берберләренә каршы куеп, канга батырып булса да, Россиянең бу бандитлар өстеннән бөек җиңүен ул да якынайтты! Бу хәтле куркыныч мәкеренә үзенә күрә аклау-аклану да тапты Фабарисов. Беренчедән, ул гомер буе шушы илгә, шушы системага хезмәт итте. Мәскәүдә КГБ беткәндә дә, монда бетеп тормады, Фабарисов беркайчан да, заманалар үзгәрде дип, органнардан эштән китмәде, аларга тугрылыклы хезмәтен дәвам итте. Икенчедән, татар егетләренең әллә кайларга китеп, әллә кемнәр өчен һәлак булуларына шушындый рәхимсез юл белән булса да чик куям дип, үз-үзен алдады ул. Өченчедән, ваххабизм кебек куркыныч чирнең Татарстанда да таралуын туктатам дип уйлады... Шуңа күрә үзенең провокаторларын Чечня өчен әзерләгәндә, Фабарисов бернинди дә вөҗдан газабы кичермәде, ул бу эшләрнең барысын да Россия өчен дип, милләт өчен, Татарстан өчен дип эшләде...

Соңгы мизгелгә кадәр барысы да Фабарисов уйлаганча, ул планлаштырганча барды. Хәйдәр белән дә шулай булды — Хәйдәр көнен көнгә, аен айга, елын елга Фабарисов сызып куйган юлдан барды, Фабарисов күрсәткән максатка эшләде. Башта ул аны ярты ел мәдрәсәгә кертеп укытып, «мөселман» ясады, аннан Алабуга милиция мәктәбенә укырга кертте.

Аннан мөселман итеп Чечняга, Хаттаб лагерьларына җибәрде, аннан Хәйдәр Чечняга милиционер буларак китте... Аннан әсир төшү уены ясап алдылар. Анысы телевизор аша чеченнарга Хәйдәрнең «мент» икәнен күрсәтү өчен кирәк иде... Дөрес, Хәйдәр чеченнар арасында «мөселман» булып йөргәндә, артык мәгълүмат ташымады, ул, бәлки, үзенең нәрсә өчен анда җибәрелгәнен дә аңлап бетермәгәндер... Ул бары тик мөселман булып уйнады. Мәскәү өчен нәкъ менә шушысы кирәк иде дә. Чөнки кичә генә мөселман булып йөргән татар егетенең бүген ОМОН составында корал тотып үзләренә каршы килүе чеченнарга күп нәрсә турында сөйләргә тиеш иде. Һәм Чечняда Хәйдәр кебек «мөселман» булып, махсус бурыч үтәп йөрүче татар егетләре шактый иде. Фабарисов һәр хак мөселманга үзенең бер провокаторын-хыянәтчесен тагып җибәрергә тырышты. Һәм менә Фабарисов, инде максатына ирештем, җиңдем дигәндә, Россиягә үзенең кемлеген исбатладым, инде генерал йолдызлары алдым дигәндә — шушы хәл. Бәлки, Мәскәү түрәләре Фабарисов эшен, аның бөек җиңүен үзләренә алмакчы, үзләштермәкче булалардыр? Бәлки, хәзер, инде Чечня канга батырылгач, Фабарисовны уеннан чыгарырга җыеналардыр? Чөнки план барып чыкты бит — моннан киткән мөселман-татар егетләрен, барысын да диярлек җыеп алып юк иттеләр! Дөрес, алар белән бергә, Фабарисовның да шактый гына егетләрен бетерделәр, әмма, нишлисең, сугыш сугыш инде... Аннан Мәскәү өчен КГБ татарлары үлсә ни дә, мөселман татарлары үлсә ни... Моның өчен ул тавыш куптарып тормас... Ә хәзер, тавыш куптару гына түгел, яныйлар, «Кемнәрне җибәрдегез?» дип сорау алалар. Ничә еллар Фабарисов җибәргән егетләрне үлем авызына тыктылар — ул чагында алар ярады, ә хәзер, бер кеше өчен бөтен Татарстанны аякка бастырырга уйлыйлар. Инде Казаннан да шалтыратып, Фабарисовка ниндидер кисәтүләр ясап азапландылар. Кремльдәгеләр аның эшеннән канәгать түгел, имеш, пенсиягә әзерләнергә кушканнар. Фабарисовның планы, аның егетләре аркасында үзләрен мактаганда, барысы да риза, барысы да канәгать иде аның эшеннән. Бер абынуы җитте, Мәскәү дә, Казан да хәзер ишеккә төртеп күрсәтә. Әмма Фабарисов болай гына ишектән чыгып китә торган кеше түгел әле ул. Үзе белән бик күпләрне ияртер ул, Казандагылар да белмәгәнгә салынып утырмасыннар хәзер. Барысын да беләләр. Фабарисовның Чечняга нинди «мөселман»нар җибәреп ятканын да белделәр, аларның үз милләттәшләрен юк итәргә баруларын да белделәр, әмма берсе дә Фабарисовны

туктатмады, киресенчә, хәлен белеп, киңәшләрен биреп, ярдәм итеп тордылар. Бу хәтле зур эшне бер Фабарисов кына ерып чыга алыр идеме? Хәзер бер Фабарисовка гына җавап тотаргамы? Юк, агайлар, сез әле аны белеп бетермисез, китсә дә, ул үзе белән сезнең яртыгызны алып китәчәк әле... Бөтенегезне дә булмаса...

«Бездән хәбәр булмыйча, ул егет яныннан китмәгез» диделәр. Ошамады карт чекистка мәскәүлеләрнең бу сүзе. Алар нәрсәнедер әйтеп бетермиләр иде. Нәрсәне? Фабарисов артык күп белә, бәлки, кайберәүләргә шул ошамыйдыр? Әмма ул үзенең турылыклы татар икәнен күптән исбатлады бит инде. Алайса, эш нәрсәдә соң, нәрсәне әйтеп бетермиләр Фабарисовка?

Һаман үлә алмыйча, кибеп, тилмереп яткан хатынын өстеннән бикләп, ул ашыгып Хәйдәр янына чыгып китте. Үзен борчыган бик күп сорауларга шунда җавап табасын сизенә иде Фабарисов. Әмма әҗәленең дә шунда буласын ул әле белми иде...

* * *

Төн уртасы якынлашты. Фабарисов һаман күренмәде. Хәйдәрнең телефоны өзелгән иде, ул беркемгә шалтырата, үзе турында хәбәр бирә алмады. Төн уртасында каядыр чыгып китү турында уйларга да ярамый иде — Хәйдәрне бу хакта кат-кат кисәттеләр. Имеш, чеченнар тарафыннан монда да һөҗүмнәр, диверсияләр булырга мөмкин икән. Нигә чеченнар монда килеп, ниндидер билгесез бер татар кешесенә һөҗүм итәргә тиешләр ди? «Чеченнар хыянәтне кичермиләр, сак бул!» диделәр аны озата килүчеләр. Нинди хыянәт? Тел төпләре кая тарта бу Мәскәү кешеләренең? Алар бит үзләре берәр этлек эшләп тә, соңыннан чеченнарга сылтап куярга мөмкиннәр...

Төн уртасы якынлашып килгәндә генә, Хәйдәр үзенең никадәр куркыныч һәм авыр хәлдә калуын аңлады. Соңгы тапкыр мондый хәлдә ул Чечняда әсир төшкәч калган иде. Хәйдәрнең әсир төшүе дә бик сәер булды, ул эшнең нәрсәдә икәнен соңыннан гына аңлады. Аны, үзе урнашкан частьтан сөйләшеп, машина белән килгән чеченнарга биреп — утыртып җибәрделәр. Хәйдәр каршылык күрсәтә башлагач, борчылмаска куштылар, болар — үзебезнең чеченнар, имеш. Шулай кирәк дип аңлаттылар. Автомат тотып хезмәт итеп йөргән җиреннән, Хәйдәр беркөнне әсир булды да куйды. Бу турыда хәбәр шул көнне үк Мәскәү телевидениесеннән әйтелде,

имеш, Татарстаннан килгән Эчке эшләр хезмәткәрен, татар егетен, чечен бандитлары әсир итеп алганнар икән... Хәбәр Идел буйларына да, Каф тауларына да таралды, бала кыяфәтле бу егетнең рәсеменә бераүләр — кызганып, икенчеләр нәфрәтләнеп карадылар, чөнки күптән түгел генә бу татар егете чеченнар арасында «мөселман» булып, Хаттаб лагерьларында укып йөргән иде...

Үзен «әсир»леккә алган чеченнар, чыннан да, Хәйдәргә зыян салмадылар, кул-аякларын бәйләп базга ташладылар да башка кагылмадылар. Хәйдәрне, инде богаулы хәлендә, дөньяның бөтен телевидениеләре күрсәтте, имеш, Татарстаннан килгән милиционер егетне ваххабилар әнә ничек вәхшиләрчә җәзалаганнар...

Бу сәер «әсир»лектә вакытта Хәйдәргә тырнак белән дә тимәделәр, ә менә башкаларның канын эчтеләр... Хәйдәр белән бергә берничә чит ил кешесе, журналистлар урланып, бирегә китерелгән иде. Менә аларны чынлап та газапладылар, үтергәнче җәзаладылар. Битлек һәм форма кигән кешеләрнең аларны ничек газаплаганнарын күреп, Хәйдәрнең башында чәче агарды. Бу әсирләрнең терелә̆й тырнакларын каердылар, тәннәренә утлы тимерләр бастылар, әгъзаларын кисеп-кисеп алдылар. Барысы да урысча-чеченча яман сүгенеп, Алла исеме белән, дин исеменнән, мөселманнар исеменнән эшләнде. Теге вакытта чеченнар арасында азмы-күпме яшәгән, бераз булса да Чаллыда мәдрәсә белеме алган Хәйдәр бу хәлләрне тетрәнеп һәм шикләнеп күзәтте. Чеченнарның мондый түгеллеген белә иде ул. Ә мөселман кешесенә мондый явызлык, адәм баласын газаплау Коръән белән тыелган. Дин җан ияләренә, хәтта хайваннарга, үсемлекләргә дә зыян салмаска өйрәтә, ә кеше турында инде әйтеп тә торасы юк. Бу җәзалауларны ныграк күзәткән саен, Хәйдәрнең аларның мөселман булуына шиге арта барды. Ә беркөнне, әсирләрне ерткычларча кыйнап, алардан канлы камыр ясаганнан соң, боларның барысын да җентекләп кинога төшереп бетергәч, җәзачылар арып ялга туктадылар. Бер читтә бөкшәеп, тын алырга да куркып яткан Хәйдәр барын алар онытканнар идеме, ниндидер сәбәпләр белән исәпкә дә алмыйлар идеме — анысын ул аңлап бетермәде. Аны телсез калдырганы башка иде — битлекләрен салган җәзалаучылар арасында ул үзе белән бер поездда килгән контрактчыларны күрде. Алар Мәскәү—Назрань поездында да үзләрен бандитлар кебек тоттылар, алар белән гади пассажирлар гына түгел, башка хәрбиләр дә бәйләнмәскә тырышты. Бу бандитлар бер вагонда хәтта проводник ингуш кызын көчләп,

поезд барышында ташлап калдырганнар дип тә сөйләделәр. Һәм менә шулар бүген чечен «әсир»легенә төшүчеләрне ерткычларча җәзалыйлар, җәзалап туйгач, суеп, атып үтерәләр, чечен телендә кычкырына-кычкырына «Аллаһ акбар!»лар әйтеп, барысын да кинога төшереп баралар...

Хәзер исә битлекләрен салган җәзалаучылар урыс телендә сөйләшеп утыралар иде. Араларында берничә чечен да бар, ахры, тау акценты сизелеп тора. Шулчак Хәйдәр үзен частьтан килеп алып киткән чеченнарны танып, тынсыз калды.

— Боларның эше бетте, — диде башкисәрләрнең берсе, канга баткан әсирләргә тибеп. — Кеше хокукларын күрсәттек бу иностранецларга! Жаль, болар өчен акча алып булмый...

— Акчага эшләгәндә кызыклырак иде. Болай бер кызыгы калмады. — Монысы чечен булды, ахры, аңкау белән сөйли. — Кино өчен генә кыйнаталар, сволочьлар!

Чеченның артык телләшеп китүе урыс башкисәрләренә ошамады.

— Син, черножопый, авызыңны чамалап ач, — диде аю кебек таза гәүдәле урыс. — Россия төрмәләреннән нәрсә өчен чыгардылар сезне?! Барыгызны да шунда черетәсе иде. Безгә барыбер — Завгаевчымы, Гантимеровчымы, Дудаевчымы... Берегезгә дә ышанырга ярамый! Теләсә кайсы вакытта аркага пычак кадарга мөмкинсез...

Сүзнең ямьсезгә китә башлавын күреп, берсе сүгенеп бәхәсне туктатты. Ул, урыныннан сикереп торып, кискен-кискен боерыклар бирә башлады:

— Боларны — расходка, — диде ул идән уртасында канга батып яткан чит ил журналистларына күрсәтеп. — Син, чечен, давай, «Аллаһ акбар»ыңны әйтеп, эшкә башла! Син, Питер бандиты, кинога төшереп бар!

Ул почмакта бөгәрләнеп яткан Хәйдәр янына килде, итеге белән аңа төртеп алды.

— Бу сатлык татарга тимәгез, аны исән-имин частька алып кайтып тапшырырга куштылар. Аны, әлбәттә, расходка җибәрсәк яхшырак булыр иде, аларның берсенә дә ышанырга ярамый. Әнә теге якта күпме татар сугыша безгә каршы?! Әмма бу этен алып кайтып бирергә куштылар. Кирәге бетмәгәндер... Тизрәк кыймылдагыз, төнгә юлга кузгалабыз...

Хәйдәр үзенең кемнәр арасына килеп эләгүен инде бөтенләй аңлап бетерде. Ул частьта вакытта ишеткән иде, әмма ышанып ук бетмәде. Бу кеше урлау, җәзалауларны спецорганнар үзләре оештыралар икән дип сөйлиләр иде. Чеченнардан Абдулкадыйров дигән бер бандиты, урыс башкисәрләре белән бергә, органнар күзәтүе астында, кешеләрне ур-

лау һәм үтерү белән шөгыльләнә икән. Моның нәкъ шулай икәненә Хәйдәр хәзер үзе дә инанды. Бу бандитлар да шул отрядтан булырга тиешләр иде.

Калган барысы да Хәйдәр күз алдында булды. Кино тасмасына төшерә-төшерә, чечен телендә нидер кычкыра-кычкыра, башта ярымүлек әсирләрне кыйнадылар, җәзаладылар. Аннан урысы-чечены «Аллаһ акбар!» дип үкереп, бу мескеннәрне берәм-берәм камера каршында атып үтерделәр... Баз идәне үлекләр белән тулды... Көл кебек күгәргән Хәйдәр почмакта берүзе утырып калды...

Төн уртасында юлга кузгалдылар. Башкисәрләр инде битлекләрен салып атканнар иде, бу тирәләрне яхшы белгәнлектән һәм үз көчләренә нык ышанганлыктан, тау-таш араларыннан тыныч кына атлый бирделәр. Бу тирәләргә күптән федераллар хуҗа иде, шуңа күрә юлда нинди дә булса куркынычка тап булырбыз дип, алар уйламадылар. Тау араларында инде таң яктысы да беленә башлаган иде. Кинәт кенә тау итәгендәге агачлар арасыннан сөйләшкән тавышлар ишетелде. Каршыга килүчеләр урысча һәм чеченча сөйләшәләр иде, араларында гарәпләр дә бар иде, ахры, алар да үз телләрендә кискен-кискен эндәшеп куялар. Шик тә юк, болар — мөҗәһитләр, боевиклар иде. Килүчеләр бу җәза отрядына караганда шактый күбрәк иде кебек, шуңа күрә урыс башкисәрләре тизрәк тау-таш арасына яшеренергә, боларның үтеп китүен көтәргә дигән фикергә килделәр. Әмма чечен боевиклары үтеп китәргә ашыкмадылар, тауның үзәнлек бер урынына туктап, киңәшә башладылар. Шул чакта Хәйдәр аермачык күрде — чеченнар куллары артка каерып бәйләнгән әсирләрне куа киләләр иде. Менә ул әсирләр, аерымланып, бер урынга тукталдылар, аларның барысы да 20—25 яшьләр тирәсендәге ир-егетләр иде...

— Ну, татар провокаторлары, гомерегез белән бәхилләшегез! — Әсирләрне озата килүче чечен автоматын аларга төбәде. — ФСБга хезмәт итүчеләрнең барысы белән дә менә шушылай булачак!

Көтелмәгән бу күренештән урыс башкисәрләре белән бергә тау араларында күзәтеп яткан Хәйдәр ташка сеңде. Татарлар! Аның каршында татар егетләре басып тора иде! Чеченнар татарларны атарга алып килгәннәр иде!

— Без хыянәтчеләр түгел, — диде татарларның уртадарак торганы. — Без дин өчен сезгә ярдәмгә килгән мөселманнар. Аллаһ белә.

Бу татар кешесенең тавышы Хәйдәргә бик таныш кебек тоелды. Әмма ярым караңгыда әсирләрнең йөзен танырлык

түгел иде. Бугазыннан чыгарлык булып типкән йөрәген салкын ташка кысып, Хәйдәр тагы тыңлый башлады...

— Син, сатлыкҗан, әле Алланы телгә аласыңмы?! — дип җикеренде автомат аскан чечен. — Монысын да ФСБда өйрәттеләрме? Ә мөселман лагерьларының кайда икәнен кем урысларга җиткереп торды?! Кем чечен авылларында боевиклар бар дип, урыс очучыларына хәбәр бирде, ул авылларны утка тоттырды?! Кем?!

— Биредә андыйлар юк. — Татар егете бик каты кыйналган иде, ахры, авырлык белән генә тын алып сөйли. — Биредә бары тик мөселманнар гына. Безне үтереп, сез өстегезгә зур гөнаһ аласыз. Провокаторлар сезнең халыкта да бар, бездә дә бардыр. Безгә алар өчен дә сугышырга, милләт өстенә ягылган бу кара тапны юк итәргә мөмкинлек бирегез.

Ул арада гарәпләр белән чеченнар кызу-кызу бәхәсләшеп алдылар. Гарәпләрнең тизрәк эшне бетерәсе дә китәсе килде, ахры, ә чеченнарның татарларга каршы корал күтәрәселәре килмәгәнлеге күренеп тора иде. Алар икеләнәләр иде, һаман суздылар.

Инде яктыра төште, әсир татарларның да йөзләрен ачыграк күрергә була иде. Хәйдәр, бу фаҗигале күренешне мәңге хәтерендә калдырырга теләгәндәй, башын күтәрә төшеп, әсир татарларга карады. Аның карашы шунда ук уртада басып торган ябык гәүдәле татар егетенә төште. Куллары артка каерып бәйләнгән егет — классташы Әхмәт иде. Хәйдәр капланып яткан таш селкенеп куйгандай булды, таш дымлы иде, бу хәлләрне күреп, таш булып таш та елый кебек иде... Хәйдәр, соңгы тапкыр күреп калырга теләгәндәй, тиз-тиз башкаларга күз төшерде. Әсирләрнең күбесе Хәйдәр белән бергә татар гимназиясендә, мәдрәсәдә бергә укыган татар егетләре иде...

Ул арада таң яктысы тау араларын тутырды. Үлем каршында басып торуларын аңлап, Әхмәт иртәнге намазга — соңгы намазына — азан әйтә башлады:

— Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр!

— Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр!

Азан тавышы өскә аварга торган кыя-ташларга килеп бәрелде, бу салкын ташлар арасында аңлау тапмыйча, кайтаваз булып, сулкылдап, киредән татарларның үзенә кайтты...

— Әшһәдү әллә-ә иләһә иллаллаһу!

— Әшһәдү әллә-ә иләһә иллаллаһу!

Азан тавышы, ярдәм көткәндәй, агачларга килеп сарылды, бу моңны, бу бәхилләшү авазын күтәрә алмыйча, агач яфраклары җилфердәп җиргә коелды, җилләр белән очты...

— Әшһәдү әннә Мөхәммәдәр-рәсулуллаһ!

— Әшһәдү әннә Мөхәммәдәр-рәсулуллаһ!

Азан тавышы йөзен ташка ящереп яткан Хәйдәрнең янына китереп бәрде, хәтерендәге иң изге, иң кадерле мизгелләрне уятты. Бу тавыш аның күңелендә әле Чулман дулкыннары булып шаулады, әле, әнисенең бишек җыры булып, сабый чагына алып китте... Тау араларында үлемгә хөкем ителгән татар егете тавышында «Туган тел» аһәңе яңгырап китте, әйтерсең лә меңьеллык «Кара урман»нар, «Тәфтиләү»ләр татар балалары белән бәхилләшәләр иде...

Татарлар барысы да намазга тезләнделәр...

Аларның богауланган килеш тә намаз укуларын күреп, гарәп-чеченнар гаҗәпкә калдылар. Аннан, сакларга берничә чеченны куеп, алар да татарлар белән бер сафка басып, намаз укый башладылар, Аллаһның гыйбадәте аларны тагы берләштергән, туганлаштырган иде... Бу хәлне күреп, җәза отряды да хәрәкәткә килде. Чеченнарның, татар егетләре белән берлектә, яңадан тау араларына кереп китәсен, яңадан бер булып, Россиягә каршы көрәшә башлаячакларын беләләр иде алар.

— Берсен дә моннан исән килеш җибәрмәскә! — диде урыс башкисәрләренең башлыгы. — Намаз вакытларында бетерәбез бу чуркаларны! Аннан ачыклап карасыннар — кем кемне үтергән!

Тау араларыннан атылып чыккан ут намаз укучыларны кыра башлады. Чеченнар һәм гарәпләр сикереп торып, коралларына ябыштылар. Ике яктан да атыш башланды. Татарларның куллары бәйле иде һәм алар ике ут арасында калдылар. Татарлар, кайсы сәҗдәдә килеш, кайсы аягүрә, утны үзенә кабул итте. Автоматлар чыкылдаган, гранаталар шартлаган, сүгенгән, кычкырган тавышлар арасыннан, бу гарасатның барысын да туктатырга, җиңәргә теләгәндәй, кыя-ташларны тәкбир тавышы тетрәтте. Татарлар тәкбир әйтәләр иде! Татарлар үлемне Аллаһ исеме белән каршы алалар иде...

Ул арада урыс башкисәрләренә ярдәмгә частьтан хәрбиләр килеп җитте. Көчләр тигез түгеллеген күреп, исән калган чеченнар тау араларына кереп югалдылар. Башкалары, татарлар белән бергә, канга батып, үзәнлектә ятып калдылар...

Җәза отрядының да күпчелеген кырып салганнар иде. Әле кичә генә ярсып әсирләрне кыйнаган һәм үтергән урыс бандитлары да, чечен ялчылары да, канга батып, үзәнлектә таралып яталар иде. Тау араларыннан тәгәрәп килеп чыккан кояш, бу хәтле мәхшәрне һәм фаҗигане күреп, күккә

күтәрелә алмый торды... Таулар катып калган иде. Үзәнлек татар, урыс, чечен, гарәпләрнең җансыз гәүдәләре белән тулган иде...

Хәйдәр могҗиза белән генә исән калды. Ул таш арасыннан башын күтәрмәде. Аның өстеннән урысы да, чечены да, гарәбе дә таптап уздылар... Ул аларның аяк астында мәет кебек ятты. Ул инде, чыннан да, мәет, тере мәет иде...

* * *

Ләйләне бүген больницадан алып чыктылар. Аны иртәгә Казанга, Арча кырындагы сары йортка алып китәргә тиешләр. Баш табиб белән әнисе шулай киңәштеләр, беркем дә Ләйләнең фикерен, теләген сорамады. Ләйләгә барыбер иде — монысыннан гына котылырга булсын. Ләйләнең тәне, җаны бу карт яһүди кулында тәҗрибә куянына әйләнде, көчле уколлар, дарулар белән миңгерәйтеп, ул аның белән нәрсә теләсә, шуны эшләде. Ләйләгә бер дә аңга килергә ирек бирмәделәр. Аның шушындый йокылы-уяулы, үлек халәтен Ләйлә өчен яхшы хәл дип аңлаттылар. Кыз инде бөтенләй ашаудан калгач, аралашмый, йөри алмый башлагач, аны Казанга җибәрергә булдылар. Әнисе елый-елый ризалашты...

Иртәгә әнисе аны Казанга алып китәргә тиеш. Әтисе, һәрвакыттагыча, исерек. Ләйлә дә үзен исерек кеше кебек хис итте, аның туктаусыз башы әйләнә, ул аягында селкенеп кенә басып тора иде... Бер көнгә булса да ирекке чыкканына куанып, әйберләргә тотынып, ул әкрен генә бүлмәдән бүлмәгә йөрде... Менә бу бүлмәдә исерек әтисе йоклап ята, ул шулай гел айный алмыйча йоклый. Икенче бүлмәдә түшәмгә хәтле аракы әрҗәләре өеп куелган. Кухняда әнисе нәрсәдер әзерләп йөри. Ләйлә юыну бүлмәсенә керде. Стенада эленеп торган зур көзгегә карады. Көзгедән аңа таныш түгел карчык карап тора иде — соры, җыерчыклы йөз, кибеп, ярылып беткән иреннәр, кыркып алынган такыр баш һәм... Ләйләнең күзләре... Зур, иксез-чиксез, хәсрәт дәрьясы кебек төпсез күзләре... Бу йөздә бары тик алар гына исән калган, хәзергә бары тик аларда гына яшәү чаткылары чагыла иде...

Ләйлә кулларына карады. Алар да саргаеп, кибеп, коргаксып беткәннәр иде. Күгәргән нечкә беләкләрен энә тишкәләп бетергән, аларда әле һаман каткан кан оешып тора иде...

Ләйлә үз тәненнән үзе чирканып китте. Больница, дару, кан исе сеңеп беткән киемнәрен тиз генә салып ташлады.

Башы әйләнүдән һәм хәлсезлектән аумаска тырышып, агып торган су астына кереп басты. Суга кушылып, күзләреннән мөлдерәп яшь акты, тәнендәге кере, җанындагы чире акты, хәсрәтле, шикле уйлары, өметсезлеге акты... Чиста су астында чиста тән һәм җан белән басып, Ләйлә елый-елый үткәннәре белән бәхилләште, ата-анасы белән хушлашты. Ләйлә бер фикергә килгән иде...

Юынып чыккач, чиста тән белән утырып намаз укыды. Зиһене тагы да ачылып, җаны тагы да сафланып, тернәкләнеп китте. Ул Аллаһтан шушы ниятен тормышка ашырырга көч сорады. Ләйлә аңлый иде — әгәр ул Казан больницасына эләксә, аннан беркайчан да әйләнеп кайта алмаячак. Анда барып эләккән кешенең әле үз аягы белән чыкканы юк, үз аягы белән чыкса да, үз акылы белән чыга алганы юк. Мөселман икәнен дә белсәләр, акылыннан гына түгел, иманыннан яздырганчы газаплаячаклар аны. Чаллы больницасында боларны күрде инде Ләйлә. Казан больницасында исә аны, чыннан да, тилереп үлү көтә иде. Әнисе моны аңламый, ул шул яһүди табибларына һаман ышана, алар белән кушылып һаман мөселманнарны сүгә, мәдрәсәне каргый. Ул хәзер Ләйләнең урам кызы булуына да риза, тик мондый Ләйлә генә булмасын, дин юлында йөрмәсен...

Ләйләнең зиһене беркайчан булмаганча ачык һәм аңлаешлы эшли иде. Ул өйдән, ата-анасыннан китәргә ният кылды. Кирәк икән, шәһәрен, хәтта илен ташлап... Кая — әле Ләйлә төгәл генә бер фикергә килмәде, әмма бары тик мөселманнар гына яшәгән урынга күчеп китәргә кирәклеген яхшы аңлады ул. Коръән шулай куша — яшәргә, дин тотарга мөмкинлек юк икән, мөмкинлек булган җиргә күчеп кит, ди. Монда Ләйлә өчен андый мөмкинлек юк, иң якын кешеләре — әти-әнисе аның дин тотуын тилелек дип кабул иттеләр, юләрләр йортына яптылар... Димәк, ата-ананың фатихасын алмыйча, аңа бу йорттан чыгып китәргә туры киләчәк...

Бәлки әле, Ләйлә Әхмәт артыннан китәр. Ул инде аның монда кайта алмаячагын белә, исән калып, монда кайтса да, бу илдә аны төрмә көтә. Димәк, алар Әхмәт белән бары тик анда гына очраша, кавыша алалар... Әхмәт авыр хәлдә калган булса, Ләйлә аны тау-таш араларыннан да эзләп табар, сулышы белән өреп терелтер, яшәтер... Исән генә булсын, ул аны барыбер эзләп табар...

Ләйлә әнисенә бернәрсә дә сиздермәскә булды. Сиздерсәң яки карышсаң, тыңламасаң, ул шунда ук больницадан бригада чакыртачак. Ул Ләйләнең бу уйларын тиле кешенең саташуы дип кенә кабул итәчәк. Ә Ләйләнең әле беркай-

чан да бу хәтле тирән һәм төпле фикер йөрткәне юк иде, җитди һәм тәвәккәл булганы юк иде... Һәм ул Аллага тапшырырга булды...

Иртәгә юлга чыгарга әнисе кичтән үк төенчекләрен әзерләп куйды. Ул Ләйләнең Казанга барып терелеп кайтасына, элеккеге шат күңелле Ләйлә буласына чын күңелдән ышана кебек иде. Ана һаман барысына да динне гаепләде. Ләйләнең бу хәлләрен бары тик диннән генә күрде. Аның бөтен теләкмаксаты — Ләйләне диннән биздерү иде. Кирәк икән — табиблар ярдәмендә, кирәк икән, иң көчле дарулар белән, кирәк икән, иң көчле сихер-гипнозлар тәэсирендә ул бердәнбер кызын Аллаһ юлыннан тартып алырга булды. Ана моны кызын коткару өчен дип эшләде, әмма кызын түгел, үзенең җанын коткарырга кирәк икәнлеген ул әле аңламый иде. Һәм аңларга инде вакыт та калмаган, билгеләнгән гомер үтеп киткән, бу хатын өчен дә күктән хәбәр килгән иде...

Төн уртасы якынлашты. Күп тәрәзәләрдә ут сүнде. Ләйләнең әнисе дә, төнгә тиешле стаканын бушатып куеп, исерек ире янына кереп ауды. Хәзер иртәнгә кадәр алар уянмаячак. Әтисе әле иртән дә аунап ятып кала, аның айныганын Ләйләнең гомумән дә күргәне юк. Ә әнисе, кичтән күпме генә эчсә дә, иртән аягөсте була, тагы тормыш арбасына җигелә, тагы дөнья куа башлый...

Барысы да йоклап беткәч, Ләйлә әкрен генә урыныннан торды. Калтыранган куллары белән сумкасыннан документларын барлап карады — алар үз урынында иде. Шыпырт кына чыгып залдан, әнисенең җыеп куйган җиреннән бераз акчасын алды, аны күлмәк кесәсенә салып куйды. Шунсыз булмый иде. Бу мәҗбүри бурлыгы өчен ата-анасыннан гафу үтенде. Билгесез юлга бөтенләй дә акчасыз чыгып китү турында уйларга да ярамый иде. Аннан Ләйлә аяк очларына гына басып ишеккә килде, ачарга дип кулларын сузды. Ишектә ачкыч юк иде.

Ләйлә, авып китмәс өчен, ишеккә сөялде. Мондый хәл буласын ул бөтенләй уйламаган иде. Ышанмыйча, ишекне тагы бер тапкыр этеп карады. Ишек бикле, ә тиешле оясында ачкычлар юк иде...

Ул арада йоклап яткан бүлмәсеннән әнисенең уфылдап әйләнеп ятканы, саташып нидер сөйләнгәне ишетелде. Ләйлә тизрәк үз бүлмәсенә ашыкты. Бүлмәсенә кергәч, ул шактый вакыт тын да алмый әнисенең кабат йокыга китүен көтте. Өйдә тагы тынлык урнашты. Ишек төбенә барып, ачкыч эзләп йөрүдән мәгънә юк иде, димәк, әнисе аны махсус җыеп куйган. Больницадан шулай өйрәтеп чыгарганнардыр, баш-

ка ата-аналарга шулай дип әйткәннәрен Ләйлә үзе дә ишеткәләгән иде. Димәк, тәрәзә генә кала. Ләйлә, аяк очларына басып, тәрәзәгә килде. Аска карады. Икенче кат кына булса да, шактый биек иде. Сикереп төшеп имгәнергә мөмкин, ул чагында — тагы больница, тагы уколлар, тагы төрмә дигән сүз. Инде аны, мәңге качмаслык итеп, бәйләп үк куячаклар...

Ләйләнең өйдән китү нияте нык, үзгәрешсез иде. Ул, кайчы эзләп табып, караватындагы җәймәне тураклап ташлады. Аларны тиз-тиз генә төйнәп тоташтырды, ныклы гына бау килеп чыкты. Ләйлә ул бауның бер башын батареяга бәйләп куйды, икенче башын, тәрәзәне ачып, урамга ташлады. Тәрәзәдән башын тыгып, Мәрьямбану апалары яшәгән якка карады — аның тәрәзәсендә келпеп ут яна иде. Ләйлә бүген төнне аларда кунар, аннан, таң белән, әнисе уянганчы ук, шәһәрдән чыгып китәр. Чөнки Ләйлә белә — әнисе иң беренче эш итеп аны Әхмәтләрдән эзләячәк, димәк, ул килеп тапканчы, Ләйләгә бу йорттан китәргә туры киләчәк...

Ләйлә, кечкенә сумкасын күкрәгенә кысып, әкрен генә бау буйлап аска төшә башлады. Аста үзен нинди зур куркыныч көтеп торганын мескен кыз бала белми иде әле... Аның бу йорттан котылырга, китәргә теләве шулкадәр көчле иде, аста котырган этләр көтеп торса да, ул барыбер юлыннан туктамас иде... Ә Ләйләне аста котырган этләр түгел, котырган кешеләр өере көтеп тора иде...

* * *

Ләйләне аста котырган өер көтеп тора иде...

Бер чеметем әфьюн өчен кая барып керергә, кемне таларга белмәгән, шул агу җитмәгәннән калтырый, котыра ук башлаган урам наркоманнары өчен Ләйлә төн уртасында күктән төшкән бәхет иде. Өер мизгел эчендә кызны уратып алды, тын алырга да ирек бирмичә, авыз-борынын томалап, аны йорт астына алып төшеп китте... Бу йортка бәла килгәнне белдереп, караңгы төндә ак бау гына озак җилфердәп, чайкалып торды...

* * *

Мәрьямбану ана төнге намазына әзерләнә... Әйтерсең лә соңгы намазына әзерләнә...

Юынып чыкты. Узган ел аңа Хаҗдан ап-ак өс-баш алып кайтканнар иде — шуларны киде. Мәрьямбану аларны, үзе дә Хаҗга барса дип, бер дә кимичә, кадерләп саклый иде.

Бүген кияргә булды. Әйтерсең лә ахирәт күлмәген киде... Йөрәген әйтеп бетергесез моңсулык басты. Шул ук вакытта күңеле тыныч, сабыр иде аның... Әйтерсең лә алда башланмаган бер гомер — бәхет-сафлыктан торган чиксезлек көтә... Әйтерсең лә ул шундый бер чиккә килеп җиткән — чын тормыш әле башлана гына... Анда инде бу дөньядагы кадерсезлекләр дә, мәкер, явызлыклар да булмаячак... Кайгы-хәсрәтләре — барысы да монда калыр... Анда — башка тормыш... Анда — мәңгелек...

Мәрьямбану инде еламый. Аның яшьләре күптән кипте инде. Йөрәкнең сызлап тора торган бер тамыры гына калды, ул да булса — улы Әхмәт. Шул тамыр җир белән күкләрне, үткән белән бүгенгене тоташтырып тора, яшәтә иде. Менә бүген ул тамыр да өзелде... Әйтерсең лә ана өчен күкләр җир өстенә ишелеп төште, үткән белән бүген буталды, хәтер сүнде, тормыш тукталды...

Мәрьямбану бу кара төндә соңгы намазын укый... Ул Аллаһтан кичерү сорый — узган гомерендәге хаталары өчен... Дингә соң килгәне өчен... Кешеләргә Аллаһ гыйлемен таратып өлгерә алмаганы өчен...

Мәрьямбану Аллаһтан мәрхәмәт сорый — калган кешеләр өчен, бәхетсез милләте өчен, бетүенә таба барган дөнья өчен...

Мәрьямбану Аллаһтан Җәннәтләр тели — үзе өчен, газиз баласы өчен, хак мөселманнар өчен...

Кара төндә, таш йортта, ап-актан киенгән бер мөселман хатыны төнге намазын, соңгы намазын укый... Тиздән ул да туктар. Бу йортта башка намаз укучы калмас... Бу йортны Аллаһның бәддогасыннан, җәзасыннан инде беркем дә туктата алмаячак... Инде күктә ишекләр ачылган, Тәкъдир китабы телгә килгән, фәрештәләр саф-саф булып җиргә иңгән иде...

Мәрьямбануның күз алдында соңгы күренеш — улының сурәте чагылып үтте. Әхмәтнең йөзен сакал-мыек баскан, куллары артка каерып бәйләнгән иде. Әнә ул, таш араларына басып, азан әйтә, караңгыда аның бөтен йөзеннән, гәүдәсеннән нур тарала... Менә фәрештәләр килеп, улының гәүдәсен күккә күтәрә башлыйлар, менә улы инде җирдән аерыла, менә аның өчен күктә бер-бер артлы ишекләр ачыла, менә улы, тоташ нурга әйләнеп, шул ишекләр аша инде мәңгелеккә китә... Ерак күкләрдән, инде мәңгелектән, улының соңгы сүзләре ишетелә:

— Җәннәтләрдә күрешербез, әнием... Җәннәтләрдә күрешербез...

Җир белән күкләрне тоташтырып торган көмеш җеп зың-

гылдап өзелә... Күктә нибары бер ишек кала. Ул да ябылганчы, Мәрьямбану улы артыннан өлгерергә, бу караңгы дөньядан мәңгелек яктылыкка күчеп калырга тиеш. Җиһаннан иңгән нур, чакыру шулхәтле көчле ки, җан шул моңга түзә алмый, сулкылдап тәненнән аерыла, бу кара җирне ташлап, мәңгелеккә күккә аша... Фәрештәләр үз канатларында бу изге җанны җиде кат күкләрнең ишеге аша уздыралар, кадерләп, Раббысы каршына китерәләр... Нурдан торган бу дөньяда ул үзе дә нурга әйләнә... Җан Мәңгелек Йортына кайта.

Аның җирдәге йорты дөм караңгылыкта, соңгы сәгатен, соңгы сулышын көтеп кала... Мәрьямбануның җаны инде бу фаҗигаләрне күрмәслек ераклыкта, биеклектә була...

***«Синең дөньяда өлешең бетте һәм бурычың үтәлде инде, Аллаһудан разый булганың хәлдә һәм Аллаһ синнән разый булган хәлдә Раббыңа кайт!»***

***Коръән, «Таң» сүрәсе, 28 нче аять***

* * *

Тимербулатның йөрәге урыныннан кубарылып чыккан кебек булды. Әйтерсең лә йөрәге белән бергә җанын да суырып алдылар, аның бертын бугазы буылып, тыны бетеп торды. Сигнал да, күккә карап, үксеп-үксеп елады да, Тимербулатның тезләренә килеп елышты. Алар икесе дә, сәерсенеп һәм хәвефләнеп, Мәрьямбану белән ике арадагы стенага карадылар. Өйдә шомлы тынлык урнашты, әйтерсең лә стенаның теге ягында кемдер үлеп ята, кемнеңдер җаны инде бу йортны ташлап, мәңгелеккә күчеп бара иде...

Күрше бүлмәдә хатын-кызларның сузып-сузып чиркәү җырлары җырлаганы ишетелә. Римма олыгайган саен керәшенлегенә тарта бара — бер генә христиан бәйрәмен калдырмый, почмакта — икона, муенда — кул яссуы тәре. Тимербулат, татарча сөйләшсә, шул җиткән дип уйлаган иде. Бу йортта татарча сөйләшеп чукыну, татарча сөйләшеп сихер, татарча сөйләшеп юкка чыгу бара. Моны хәзер Тимербулат та аңлый башлады. Инде үзе генә саташу җитмәгән, урамы-урамы белән хатын-кыз җыеп алып керә. Алар төннәр буе шәмнәр яндырып, кәрт ачып, тәлинкәләр әйләндереп, рухлар, мәетләр белән җенләнеп чыгалар. Кешеләрне

бозу өчен әллә нинди сулар, төнәтмәләр әзерлиләр. Бу сасыдан, күңел болгаткыч укшыткыч исләрдән өй үләксә базына охшап кала. Бу хатыннар бары да карадан киенгән, Римма үзе дә кап-кара, алар бу секталарын үзара «кара магия» дип йөртәләр, башкаларның гаиләләренә, тормышларына шушы пычраклары белән барып керәләр, тирә-якны агулап яталар иде...

Тимербулат торган саен Мәрьямбануның нур сирпеп торган чиста өен сагына башлады. Анда һәммә нәрсә актан шул — тәрәзә пәрдәләре дә, мендәр тышлары да, өстәл җәймәләре дә... Мәрьямбану үзе дә гел актан киенгән була... Йөзеннән һәрвакыт нур, яктылык бөркеп тора...

Менә хәзер, еллар үткәч кенә, Тимербулат үзенең нәрсәне нәрсәгә алыштыруын аңлый башлады. Әйтерсең лә аның күзен каплап торган ниндидер элпә төште, Римманы да ул үтәдән-үтә күрде — бөтен азгынлыгы, бозыклыгы, каралыгы белән... Аның бу хатын белән тизрәк арасын өзәсе, яңадан үзенең ак өенә кайтасы килде, әмма Римманың сихере, кара көче аны ычкындырмады. Соңгы вакытта Тимербулатның, төрле сәбәпләр табып, Мәрьямбану янына кереп-чыгып йөрүе дә — шул Римманың тәэсиреннән котылырга, качарга тырышуы иде. Әмма һаман кача алмады, котыла алмады, миңгерәйгән, агуланган кебек, төнгә тагы шушы кара хатын янына кайтып егылды.

Тимербулат хатыннар утырган бүлмәгә якынрак килде. Ярым караңгыда, төтен һәм ис эчендә Римма хатыннарга үзенең серләрен өйрәтә иде.

— Ир-атны бары бер генә юл белән сихерләргә, мәңгегә үзеңә каратырга була, — диде ул, хатыннарга якын ук килеп. — Шуны... тамызып эчерәсең. — Ул сыекчаның исемен әйтте. Тимербулат, укшып җибәрмәс өчен, авызын куллары белән тотты. — Әйе, әйе, — дип дәвам итте Римма шашынып калган хатыннарга карап. — Мин үземнекенә дә шуны эчердем. Әле яткан булыр иде шул фанатичкасы белән.

Үзендә СПИД икәнен белгән мизгелдән, Римма бөтен дөньясына кара үч тотып, бөтен дөньяны үз артыннан ияртерлек булып котырына иде. Ул соңгы сәгатенә кадәр бу үлем чирен башкаларга да таратырга ант итте. Тимербулатны да үз куллары белән Мәрьямбануы янына кертеп куячак Римма, ул мөселман хатыны да бетсен, СПИДтан черсен! Үләннәренә, төнәтмәләренә, уколларына да бу агуны тамызачак, аның бусагасын атлап керүчеләргә ул мәңгелек бүләк әзерли. Рәхәтләнсеннәр! Дин сихерчеләр янына йөрүдән тыя, менә хәзер йөрүләренең әҗерен күрсеннәр! Нигә бер Римма гына,

шаулап яшәп ятканда, бу дөньядан китәргә тиеш? Кемгә кулы җитә, ул барысын да үзе белән алачак...

Ванна бүлмәсендә Тимербулатның үкерә-үкерә укшуын ишетеп, Римма аның янына йөгереп чыкты. Тимербулат сыгылып төшкән, әйтерсең лә аның бөтен эчләре, күзәнәкләре, кан тамырлары актарыла иде. Римма «Тимур, Тимур!» дип, аның янында бөтерелә башлады.

— Кит! — Тимербулат Римманы читкә этеп җибәрде. — Җирәнгеч! Кит янымнан!

Римма эшнең нәрсәдә икәнен шунда ук аңлап алды — Тимербулат тыңлап торган иде. Риммага хәзер барыбер иде — беләме Тимербулат Римманың үзен нинди юл белән каратуын, юкмы... Бөтен дөнья белсә дә, барыбер иде. Чөнки аның канында үлем чире, аның көннәре инде санаулы гына калган иде. Әмма бу кара хатын көннәренең генә түгел, сәгатьләренең, хәтта минутларының да санаулы гына калып баруын белми иде әле...

— Нигә мин китәргә тиеш әле бу йорттан?! — диде ул Тимербулатка, бөтен зәһәре һәм агуы белән карап. — Син кит. Син бит монда килгән килмешәк!

Тимербулат каршында бөтенләй чит-ят хатын басып тора иде. Аның чәчләре тузгып, тирле кара-кучкыл йөзенә ябышкан, ачык изүеннән тәресе елкылдап күренеп тора. Гәүдәсе җәелгән, шәлперәйгән, үзе төтен белән ысланып, бөтен дөньяга үлек исе, үлем исе тарата кебек иде...

Күңеле болганып, Тимербулат йөзен читкә борды.

— Китәрмен, — диде ул, Риммага карамый гына. — Минем тормышымның иң зур ялгышы, иң зур гөнаһысы, пычрагы — син булгансың икән... Кемне кемгә алыштырдым бит! Кемне кемгә...

— Бар, кит, — диде Римма, зәһәр ысылдап. — Әмма белеп кит! Хатыныңа бүләк белән китәсең бу йорттан, күчтәнәч белән китәсең. Миннән СПИД таптылар!

Әйтерсең лә Тимербулатның бөтен кан тамырлары берьюлы шартлады, бөтен тәне, гомере, тормышы бер мизгелдә җимерелеп төште, юкка чыкты. Ул күзәнәкләре буйлап үлем чиренең чабуын сизгән кебек булды, ул инде аның канына менә шушы хатын булып, сихер булып, үләт чире булып күптән күчкән иде, яшәп ята иде. Тимербулатның тимердәй тәнендә сәламәт өлеше калмаган, җанына да күптән адәм кыяфәтле шайтан хуҗа булып алган иде...

Римма, берни булмагандай, кара киемнәренә уралып, сихерче хатыннар янына кереп бикләнде. Йортка чиркәү җырлары, каргыш һәм бәддогалар, шайтан такмаклары таралды.

Йорт, шуларны үзенең таш кочагына алып, фаҗигасе тирәли соңгы әйләнешенә, соңгы сәгатенә керде... Әҗәл инде бу Йорт өстенә үзенең канатларын җәйгән, газап фәрештәләре адәмнәрнең баш очларына килеп басканнар, кешеләрнең соңгы сәгатьләре җиткән иде...

* * *

Өер, Ләйләне өстерәп, йорт астына алып төшеп китте. Ярым караңгы бу урын сәер җан ияләреннән мыжгып тора иде. Кеше дисәң, аларның күбесе аякка басалмый миңгерәеп идәндә ауный, җанвар дисәң, аларда әле кеше кыяфәте бар. Идәнгә ертык матраслар, чүпрәк-чапрак өелгән. Бер читтә янып беткән калай савытлар, пычрак шешәләр, шприцлар ауный. Монда ир-атны хатын-кыздан аерып булмый, монда милләт тә юк, монда миңгерәйгән бәндәләр, тере мәетләр өере генә... Ләйләне үзләре арасына төртеп еккач та, алар әллә ни кызыксыну күрсәтмәделәр. Аркылы-торкылы гәүдәләр арасында бу гәүдәне күрмәделәр дә, сизмәделәр дә...

Әмма бирегә Ләйләне алып керүчеләр бик тере һәм ярсыган иде. Алар, беренче эш итеп, Ләйләнең сумкасын тартып алдылар, аннан акча эзли башладылар. Акча аз чыкты. Наркоманнарга бу хәл ошамады. Алар Ләйләне өстерәп торгызып, аннан алтын-көмеш бизәнү әйберләре эзләргә тотындылар. Алары да юк иде. Бу наркоманнарны тагы да ярсытты, алар, үлем дәһшәте белән, Ләйләне йолыккалый, ботарлый башладылар. Шулчак Ләйлә араларыннан берсен танып та алды, бу — Әхмәтләрнең күршесе Вова дигән егет иде. Ул елый-елый аңа ялына башлады. Кызның үзен тануы Вованы ярсытты гына, хәзер аңа моннан тереләй чыгу юк иде. Корбан акчалы булмаган икән — гомере белән түләсен. Аларда закон шундый. Ул Ләйләне наркоманнар өере арасына сугып екты.

— Ты! Мусульманка паршивая! Ваххабистка! Сейчас мы в твою задницу СПИДометр поставим! — Вова, селәгәйләрен агызып, акырырга, өстендәге киемнәрен өзгәләргә тотынды. Өер дә җанланып китте, идәндәге чүпрәк-чапраклар кыймылдый, хәрәкәтләнә башлады, пычрак куллар төрле яктан Ләйләгә сузылды. Кемдер аның башындагы яулыгын сыдырып төшерде. Яулык астыннан кырылган шома баш килеп чыкты. Ул укол эзләре белән тишкәләнеп, күгәреп беткән иде. Вова моны көтмәгән иде, ул, чирканыч әйбер күргәндәй җирәнеп, читкә сикерде. Башкалар да Ләйләнең кыяфәтеннән әсәрләнеп калганнар иде.

— Да она же псих! Псих!

Псих сүзе наркоманнарга чыбыркы белән суккандай тәэсир итте, туктатты. Бар да, яңа әмер көткәндәй, Вовага карадылар. Бу тиле кызны көчләп ятудан мәгънә булмаганын Вова үзе дә аңлады, әмма аны моннан исән чыгарырга да ярамый иде. Шулчак йорт почмагында әллә нинди сәер кыштырдау авазы ишетелде. Менә ул кыштырдау куркыныч гүләүгә, гөрелдәүгә әйләнде. Барысы да, Ләйләне онытып, хәвефләнеп шул якка текәлделәр. Йорт почмагындагы караңгы баздан йөзләгән, меңләгән күселәр өере кубарылып чыгып, бу якка таба килә иде. Менә алар, гөпе-гөпе йөгереп, болар янына килеп җиттеләр, бернинди курку белмичә, шашкан кебек, идәндә аунаган наркоманнар өстенә менеп киттеләр, аларны таптый-изә, чиный-чиный, урам якка ыргылдылар. Әйтерсең лә аларны арттан күзгә күренмәгән зур афәт, куркыныч куа килә иде...

Наркоманнар арасында да ыгы-зыгы купты. Алар төрле якка мүкәли, торырга азаплана башладылар. Әйтерсең лә идәндә күселәрдән һәм кешеләрдән торган чирканыч йомгак тәгәри иде. Наркоманнарның тора алмаганнары шунда ятып, аунап калды, йөри алганнары, күселәр белән бергә, урамга атылды. Ләйлә дә, сумкасын эләктереп алып, өскә, урамга йөгерде. Ләйләгә ябышкан наркоманнар да аның артыннан ыргылдылар. Баскыч төбе шашынган кешеләр һәм күселәр белән тулган иде. Алар чинашып, үрмәләп, инде берсенберсе таптап һәм изеп, урам буенча йомгак булып тәгәриләр иде.

Ләйлә атылып подъездга керде. Һәр ишекне елап дөбердәтә-дөбердәтә, өскә йөгереп менә башлады. Йортта аңа бер генә ишек тә, хәтта ата-анасы ишеге дә ачылмады, барысы да үлек йокысы белән йоклыйлар иде... Ә арттан, үкереп, тилереп, наркоманнар төркеме куа килә иде...

Ләйлә һәр ишек саен дөбердәтеп вакыт әрәм итүен туктатты, чөнки барыбер беркемнең дә ачмаячагын аңлады ул. Аның бөтен өмете — тугызынчы каттагы Хәйдәрләр квартирасы иде. Ул Аллаһтан елый-елый өйдә кем дә булса булуын сорады, соңгы көчен җыеп, йөрәгенең соңгы тибешләрен санап, Хәйдәрләр ишегенә килеп капланды. Наркоманнар төркеме инде куып җитеп килә иде...

— Хәйдәр!!! — дип кычкырып җибәрде Ләйлә бөтен подъездны яңгыратып. — Ач, Хәйдәр, үтерәләр!

Ишек ачылып китте. Аңын җуйган Ләйлә Хәйдәр кулына авып төште...

* * *

Хәйдәр Фабарисовны көтә иде. Ишек артында сәер дөбердәү һәм ачыргаланып кычкырган хатын-кыз тавышын ишетеп, ул шашынып калды. Бу — Ләйлә тавышы иде! Хәйдәр ишекне каерып ачып җибәрде... Аңын җуйган Ләйлә аның кулларына авып төште... Аста наркоманнарның дөпелдәшеп йөгерүләре, гыжлап тын алулары һәм сүгенүләре ишетелә иде. Хәйдәр ишекне ашыгып бикләп куйды.

Ләйлә аңына килде. Алар, гаҗәпләнеп һәм куркышып, бер-берләренә озак кына карап тордылар. Хәйдәр Ләйләгә куркып карады, чөнки бу — ул белгән, аның белән бер гимназиядә укыган алсу битле, бөдрә чәчле Ләйлә түгел иде. Хәйдәр каршында йөзе саргайган, башына чорнап яулык ураган ябык, хәлсез бер кыз утыра иде. Бары тик зур моңлы күзләре һәм тавышы гына бу кешенең Ләйлә икәнлеген, Хәйдәр өзелеп яраткан, һаман уйларында, хыялында йөрткән Ләйлә икәнлекне аңлаталар иде.

Ләйлә дә Хәйдәргә сәерсенеп һәм гаҗәпләнеп карады. Аның Хәйдәрне инде берничә ел күргәне юк иде. Аның каршында олыгайган һәм тупасланып, җитдиләнеп киткән чит ир-ат утыра иде. Ә бит Ләйлә аның үзе белән бергә йөгерә-йөгерә гимназиягә йөргән вакытларын хәтерли, Әхмәт белән икесенең яшерен генә Ләйлә өчен көрәшкәннәрен, ярышканнарын белә. Аларның өчесен аерып алып булмый иде. Ә тормыш аерды да ташлады менә. Аеру гына түгел, җан дусларны бер-берләренә каршы корал тоттырып бастырды...

Ләйлә Хәйдәрнең ОМОН составында Чечняга киткәнен белә иде. Ә Хәйдәр Ләйләнең психбольницада ятканын, аның өеннән качып чыгып баруын белми иде. Хәйдәр мондагы күп нәрсәләрне белми иде, чөнки ул соңгы вакытта башка дөнья, башка тормыш белән яшәде. Мөгаен, ул әле Әхмәтнең дә Чечняга киткәнен белмидер. «Һәм белергә дә тиеш түгел, — дип уйлады Ләйлә, Хәйдәрне каш астыннан гына күзәтеп. — Алар хәзер балалык дуслары түгел инде. Үз теләкләре белән берсе — Аллаһка, икенчесе — шайтанга хезмәт итә». Һәм менә Ләйлә, ихтыярсыздан, шушы йортка килеп керде, Хәйдәрдән ярдәм сорарга мәҗбүр булды.

Хәйдәр һәр минут саен Фабарисовның килеп керүеннән курка иде. Фабарисов килеп керер дә Хәйдәр Ләйләгә әйтергә тиешле сүзләрен әйтә алмый калыр. Ә Хәйдәр әйтергә тиеш ул сүзләрне, үзе күргән, кичергәннәрне кемгә булса да сөйләп калырга тиеш ул. Чөнки Фабарисовның юкка гына килмәвен сизенә Хәйдәр. Чөнки ул Чечняда органнарның

шулкадәр явызлыкларын һәм мәкерен күрде инде, алардан теләсә кайсы вакытта, теләсә нинди этлекне көтәргә мөмкин икәнен белә. Ул артык күп белә иде... Ул тоткыннарны органнар үзләре урлаганны белде һәм чит ил журналистларын урыс башкисәрләре җәзалап үтергәнне күрде. Ул тау араларында коточкыч фаҗиганең шаһиты булды — утыз сигез татар егетен ничек һәм кемнәр атып үтергәнен күрде. Аны моңа кадәр вак-төяк эшләрдә файдалансалар, хәзер зур хыянәткә — ике мөселман халкы арасында дошманлык тудыруга тарталар иде. Хәйдәр, ул канлы вакыйганың бердәнбер исән калган шаһиты буларак, утыз сигез татар егетен чеченнар үтерде дип әйтергә тиеш иде. Шулай әйтми икән, аның үзенә дә яшәү юк иде. Хәйдәрдән Мәскәүдә болай әйттерә алмадылар. Ни сәбәпледер монда кайтардылар. Төн уртасында Фабарисовның килергә чыгуы да юкка түгел иде. Ул Хәйдәрне үзе белән алып чыгып китәргә дә мөмкин. Шул китүдән бөтенләйгә юкка чыгуың да бар — сугыш вакыты, чеченнар үтергән, диярләр, һәм — бетте-китте. Шуңа күрә Хәйдәр анда күргән хәлләрне кемгә булса да сөйләп калырга тиеш иде. Бу кадәр куркыныч сер белән Хәйдәр алга таба яши алмый, үзенең, хаклыкны белеп тә, аны яшереп йөрүе Хәйдәрнең җанын талый, аңа яшәргә ирек бирми... Ләйләнең Әхмәт белән нәрсә булганын белергә бигрәк тә хакы бар, алар инде өйләнешергә йөриләр иде бит. Ләйлә Хәйдәрне түгел, Әхмәтне сайлап алган иде...

Вакыт кыса... Менә-менә Фабарисов килеп керергә тиеш. Хәйдәр сизенә — дөреслекне әйтергә башкача мөмкинлек булмаячак. Ул дөреслек мәңгегә Хәйдәрнең үзе белән китәргә мөмкин. Димәк, Ләйләгә барысын да сөйләп калырга кирәк.

— Ләйлә, — дип башлады ул сүзен бик нык дулкынланып. — Сине монда Ходай үзе җибәргән. Минем сиңа Әхмәт турында хәбәрем бар.

Ләйләнең күзләре зур булып ачылды, ул, куркып һәм шикләнеп, Хәйдәргә төбәлде. Хәйдәр Чечняда мөселманнарга каршы сугышкан кеше, шуңа күрә Әхмәт турында да теләсә нинди ялган сөйләргә мөмкин дип уйлады ул. Ләйлә инде монда ник кергәненә үкенә башлаган иде. Ләкин Әхмәт турында беләсе килү бик көчле иде, шуңа күрә ул, шикләнә-шикләнә булса да, Хәйдәрне тыңларга уйлады.

— Беләм, син миңа ышанып бетмисең, — дип дәвам итте Хәйдәр, Ләйләнең үзенә шикләнеп каравын күреп. Ул пыяла шкаф янына барды, кулына Коръән алды. Шул Коръәнне күкрәгенә кысып, Ләйлә каршына килеп басты. Эшнең

артык җитди икәнен аңлап, Ләйлә дә хәвефләнеп аягүрә басты.

— Кулымда Коръән, мин сөйлисе сүзләр бар да дөрес, Ләйлә, — диде Хәйдәр.

Калганын Ләйлә төштәге кебек кенә тыңлады һәм аңлады... Әмма Хәйдәрнең һәр сүзе, яшен язмасы булып, Ләйләнең бәгыренә уела барды, ул күренешләр мәңгелеккә хәтеренә сеңеп калды... Әнә биек кыя-таулар... Әнә тау арасына атылырга тезелгән татарлар... Алар арасында Әхмәт тә бар... Чеченнар аларны, хыянәттә гаепләп, атар өчен алып чыкканнар... Менә Әхмәт иртәнге намазга азан әйтә башлый... Татарлар барысы да намазга тезләнәләр. Чеченнар һәм гарәпләр дә, сакка берничә кеше куеп, намаз укый башлыйлар... Менә аларны күзәтеп яткан урыслар, мөселманнарның намаз вакытыннан файдаланып, алар өстенә ут ачалар... Чеченнар да, тизрәк коралларын алып, урысларга каршы ташланалар... Куллары бәйләнгән әсир татарлар ике ут арасында кала... Ул арада урысларга ярдәм килеп җитә... Исән калган чечен һәм гарәпләр качып китәргә мәҗбүр булалар... Татарлар, яу кырында тәкбир әйтеп, шәһит китә... Алар арасында Әхмәт тә була... Әхмәт тә була... Әхмәт тә була...

Калтыранган кулларына Коръән тотып, Хәйдәр сөйләп бетерде. Ләйлә озак кына бер ноктага текәлеп, сүзсез утырды. Колагында әле тәкбир тавышы, әле Әхмәтнең аерылганда «Җәннәттә очрашырбыз, җаным!» дигән сүзләре яңгырады.

— Ә син? — Ләйләнең беренче соравы шул булды.

Хәйдәр аңламады.

— Нәрсә — мин? Мин аларга атмадым, Ләйлә, анысына Алла шаһит, атмадым. Минем кулымда коралым да юк иде...

— Аларның үлемендә синең гаебең бармы?

Коръән китабы авыраеп, Хәйдәрнең кулларын, тәнен, җанын баса башлады. Ул аны кая куярга белми иде. Ул Ләйләгә нәрсә дип җавап бирергә белмәде.

— Аларның үлемендә синең гаебең бармы? — дип тагы бер тапкыр сорады Ләйлә.

Тормышның үзе кебек үк гади һәм аяусыз сорауга җавап булмады... Ләйлә урыныннан кузгалды. Ул үзенең бу өйгә ялгыш кына килеп керүен аңлады. Әмма бу өйгә кермичә, ул дөреслекне дә ахырынача белмәгән булыр иде. Егерме яше яңа тулган, инде сөйгән ярын да, ата-анасын да югалтып өлгергән, больницада әҗәл газапларын күргән кыз бала өчен дә бу дөреслек артык авыр һәм рәхимсез иде. Бу фаҗиганең

никадәр тирәнлеген, бу яраның инде мәңгелек булуын һәм беркайчан да төзәлмәячәген ул әле үзе дә аңлап бетерми иде... Мөселманнарның бу фаҗигасе алдында Ләйләнең үз газаплары, үз хәле әһәмиятсез булып, кечерәеп калды. Тәкбир әйтеп үлгән утыз сигез татар аның хәтеренә утлы тамга булып уелып калды. Шул утыз сигез татар арасында аның сөйгәне, бердәнбере Әхмәт тә бар иде. Һәм шушы канлы вакыйга турында дөреслекне Ләйлә бөтен дөньяга сөйләргә, бөтен дөньяга җиткерергә тиеш иде...

Күңеленең бер читендә, яшерен генә, кыяр-кыймас кына бер өмет, уй да сулкылдый иде. Бәлки әле, Әхмәт исән калгандыр? Хәйдәр бит аның үле гәүдәсен күрмәгән. Бәлки, ул да чеченнар белән тау араларына качып өлгергәндер? Бәлки, яралы хәлендә, урыс төрмәләрендә, больницаларында ятадыр. Сугыш вакытында нинди генә могҗизалар булмый бит. Кешене үлгән дип уйлыйлар, табуты кайта, күмәләр, ә ул көннәрдән бер көнне исән-сау кайтып керә. Ләйлә җаны-тәне белән Әхмәтнең исән булуын тели иде, шуңа өметләнә, шул фикергә генә ышана иде.

Ләйлә бу йорттан ныклы фикер белән, бөтенләйгә дип чыгып китте. Ул шушы хакыйкать артыннан, Әхмәтнең эзләреннән үзе барыр, кабере бар икән — каберен эзләп табар, гәүдәсе юк икән — үзен эзләр, аны белүчеләрне эзләр, дөреслекне эзләр... Хакыйкатьне барыбер табар һәм аны кешеләргә җиткерү өчен бөтен гомерен багышлар... Кирәк икән, кулына корал алыр, намусын һәм динен, Әхмәт кебек, кулына корал алып яклар, корал белән саклар.

Ләйлә, шундый ният белән, бу күселәр һәм наркоманнар оясын ташлап, юлга чыга... Бу бәхетсезләр шәһәрен, бу кяферләр илен дә инде мәңгегә калдыра ул... Кыз Мәрьямбану апасы янына да кереп тормаска булды, чөнки Әхмәт турында чын дөресен үзе белми торып, ялгыз анага бу хәбәрне җиткерергә ярамый иде. Ләйләне инде төн караңгылыгы да, урамдагы хәшәрәтләр өере дә куркытмый иде. Ул барысын да Аллаһка тапшырды...

Ләйлә китте... Тиздән бу йортка киләчәк утлы гарасаттан Аллаһы Тәгалә Үзе бу мөселман баласын тартып алды... Бәндәсе өчен нәрсә хәерле икәнен Ул Үзе белә иде... Бәндәләрне дә, тәкъдирләре буенча, Ул Үзе йөртә иде...

Хәйдәр, кулына Коръән тотып, идән уртасында, хәсрәт дәрьясы уртасында басып калды... Ул әле һаман ышанып, Фабарисовны көтә иде. Иблис юлга чыккан иде... Үз үлемен эзләп, әҗәленә каршы...

* * *

Хәррис ачык ишеккә килеп керде...

Хәйдәр, кулына Коръән тотып, идән уртасында басып тора иде. Бу сәер хәлне күреп, Габарисовның күңеленә шик килде. «Әллә мәскәүләр әйткән хәбәр дөресме икән» дип уйлады ул, Хәйдәрнең килеш-кыяфәтенә карап.

Габарисов ишекне ябып куйды. Түргә үтте.

— Син нишләп йөрдең анда, Чечняда? — дип үзе усалланып сүз башлады ул.

— Ә сез мине Чечняга нәрсә эшләргә җибәргән идегез соң? — Хәйдәр дә, сүзне сузып тормыйча, җанын иң борчыганнарны гына сорарга булды. — Башта — мөселманнар арасына, аннан — ОМОН составында... Бу очраклы хәлме, Хәррис абый, әллә махсус шулай эшләдегезме?

Габарисов гаҗәпләнеп үк калды — малайның башы эшли башлаган иде. Монда вакытта бозауның да бозавы булган Хәйдәрнең теле ачылган. Сөйләшү мондый һөҗүм-сорау рәвешен алыр дип Габарисов көтмәгән иде, чөнки моңа кадәр Хәйдәр, нәрсә кушсаң да, елмаеп, «ярый, абый» дип кенә тора иде. Габарисовка ул үзе дә, әнисе дә, коткаручысы, рәхмәт фәрештәсе итеп карый иде. Маңгайга терәп мондый сораулар бирергә ул беркайчан да батырчылык итмәде. Димәк, нәрсәдер үзгәргән, нидер яки кемдер малайга бик нык тәэсир иткән.

— Сиңа Чечняга кем булып китсәң дә, кайчан китсәң дә, барыбер түгел идемени?

— Барыбер түгел иде. Чөнки мин анда үлем күзенә карап йөрдем...

— Карап кына йөрдең шул. Башкалар кебек үлем күзенә барып кермәдең. Аермасын сизәсеңдер, күрәм, бик акыллыга әйләнеп кайткансың.

Шомарып беткән карт чекист белән беркатлы татар егете арасында сөйләшү әнә шулайрак барды. Габарисов беркайчан да койрыгын тоттырмады, һәртөрле хәлне үз файдасына борып, кешенең үзен гаепләп калдыра белә иде ул. Бу юлы да ул Хәйдәрне сорау-җаваплары белән шактый изде, шактый тәпәләде. Хәйдәр дә, яшьләрчә үҗәтләнеп, тискәреләнеп, һаман бер сүзне кабатлады: «Габарисов аны нинди максат белән Чечняга җибәргән?» Икесе дә үзләренә кирәк сорауларга тулы җавап ала алмадылар, икесе дә бу авыр сөйләшүдән канәгать түгел иделәр.

Габарисов, теманы бераз үзгәртеп, башка мәсьәләгә күчеп карарга булды.

— Татар егетләрен чеченнар атканны нигә өздереп әйтмәдең телевизордан? — дип сорады ул, Хәйдәр көтмәгән яктан китереп бәрергә уйлап.

— Чөнки татарларга чеченнар атмады. — Хәйдәр дә Фабарисовның күзләренә усал итеп, батырып карады. — Татарларны урыс бандитлары атып үтерде! Сез моны миннән яхшырак белергә тиешсез!

Менә нәрсәдә икән хикмәт! Хәзер Фабарисов барысын да аңлады. Менә нигә Мәскәү үрле-кырлы сикерә икән! Бу малай белергә ярамаган нәрсәләрне белгән, күрергә ярамаган нәрсәләрне күргән икән бит! Һәм Мәскәүгә кирәгенчә сөйләмәгән. Бу малай хәзер Мәскәү өчен куркынычка әйләнгән, ул хәзер әйтергә ярамаган нәрсәләрне дөньяга чыгарырга мөмкин.

Ул чагында, нигә аны монда кайтарганнар, егетне шыпырт кына юк итү аларга берни тормый иде бит?!

Карт чекистның эченә шом керде. Бу егетне юкка гына монда кайтармаганнар. Хәйдәрнең ышанычсыз икәнен белеп алгач, нигә аны телевизордан күрсәтеп торырга, нигә монда өстерәп кайтырга, нигә шушы маңка малай өчен бөтен Татарстан органнарын аякка бастырырга? Нәрсә ята моның төбендә, шулхәтле күп белеп тә, исән калдырганнар икән, юкка түгел бит инде бу? Димәк, аның әле тагы кирәге бар, бу егетне тагы нәрсәдәдер файдаланырга телиләр. Әмма — нәрсәдә?

Фабарисовның хәвефле сорауларына җавап биргәндәй, кесә телефоны зеңгелди башлады. Фабарисов кабаланып телефонга ябышты. Тагы Мәскәү иде.

— Сез урындамы? — дип сорадылар аннан коры гына.

— Әйе, икебез дә монда, — дип җавап бирде Фабарисов, тагы нәрсәдер ишетергә өметләнеп.

— Хәзер төнге яңалыкларны карагыз, — диделәр Мәскәүдән. — Сөйләшү шуннан соң булачак. Бер җиргә китмәгез. Хәбәр көтегез.

Монысы тагы да сәеррәк иде. Нигә Фабарисовны, төн уртасында монда китереп, яңалыклар караталар? Нинди хәбәр көтәргә кушалар аңа, нигә әйтеп бетермиләр? Нәрсә ятыр моның астында? Мәскәү бит бер генә адымын да уйламыйча, юкка эшләми. Нигә Фабарисов аңлап бетерми соң эшнең кайсы якка барганын? Нәрсә яшерәләр аннан? Ни өчен яшерәләр — ул аларга ярты җиңүне эшләп бирде бит инде. Әллә аның шушы хәтле оста эшеннән көнләшеп, нәтиҗәне, җиңүне бары тик үзләренеке генә итәселәре киләме? Югыйсә мөселманнар арасына «мөселман» провокаторларын кертү,

шулай итеп чеченнарны эчтән җимерү, эчтән какшату — Фабарисовның табышы бит! Хәзер бу эш өчен рапорт бирергә ашыгучылар — генерал погоны алырга теләүчеләр күптер шул Мәскәүдә. Әллә кайдагы кечкенә бер шәһәрдә корт кебек эшләп яткан карт чекист белән бүлешәселәре килмидер бу җиңүне...

Фабарисов телевизорны куеп җибәрде.

— Хәзер Чечня турында мөһим хәбәр булачак, — диде ул үзенә гаҗәпләнеп карап торган Хәйдәргә. — Карарга куштылар. Утыр, соңыннан сөйләшеп бетерербез.

Ул бу сүзләрен болай гына, Хәйдәрне тынычландыру өчен генә әйтте. Чөнки Хәйдәр, үзенә урын таба алмыйча, ишеклетүрле йөренә, хатирәләрендә казынып, һаман нәрсәдер эзләнә иде. Фабарисов аннан шикләнә башлады. Чечнядан күп кенә спецназ егетләре йә ерткычка әйләнеп, йә тилереп кайталар... Хәйдәр дә вакыты-вакыты белән ычкынган кешене хәтерләтә иде. Әгәр Мәскәү мәҗбүр итмәсә, Фабарисов монда бер минут калмас иде. Әмма — хәбәр булыр, диделәр, көтәргә куштылар...

Тапшыру беренче кадрлардан ук Чечнядан хәбәрләр белән башланды.

«Чечняда ислам террористларына каршы операция дәвам итә, — дип башлап китте диктор үзенең сүзен. — Россия спецорганнары да бу көрәштә үзләреннән зур өлеш кертәләр. Кызганычка каршы, алар арасында югалтулар да юк түгел. Безнең кулыбызга чечен боевиклары төшергән уникаль кинотасма килеп керде. Сезнең игътибарыгызга хәзер шуны тәкъдим итәбез».

Кинотасманы күрсәтә башладылар. Бу — чечен сугышчыларының әсирләрдән сорау алу күренеше иде. Фабарисов дерт итеп китте — әсирләр арасында аның берничә егете дә бар иде! Әгәр бу кадрларда Шамил Басаев белән Хаттаб булмаса, Фабарисов бу киноны органнар эше дип кенә бәяләр иде. Әмма монда Шамил Басаев белән Хаттаб үзләре сорау алалар, ә әсирләр арасында, чыннан да, берничә КГБ татары бар. Әмма бүлмәне тутырып утырган башка сакалмыеклы татарлар Фабарисовка таныш түгел, алар чын мөселманнар булырга охшаганнар, әмма чеченнар аларның барысын да хыянәтчеләр дип атыйлар, Россия органнарына хезмәт итүдә гаеплиләр. Менә бу җавап тотканы, чыннан да, Фабарисов егете, ул үзенең ФСБга эшләвен дә, майор дәрәҗәсендә булуын да әйтеп бирде. Үзенең Масхадовны шартлатырга тиеш булуын, Хаттаб һәм Басаевны үтерергә җай эзләвен дә сөйләде, аңа бу бурычны... Татарстаннан Фаба-

рисов дигән полковник билгеләгәнне әйтеп бирде. Фабарисов утырган урындыгына сеңде. Бөтен дөньяга исеме яңгырау — аның өчен үлемгә хөкем итү белән бер иде, бу, чыннан да, үлемгә хөкем итү иде...

Сорау алу дәвам итте. Егетләрнең кайсы Чаллыдан, кайсы Бөгелмәдән, Әлмәттән, Минзәләдән иде... Аларның баскан бере, үлемнең күзенә туры карап, «Мин — мөселман, бары тик Аллаһның гына колы» дип җавап бирде. Чеченнар үзләре дә аптырашта калдылар — кем чыннан да мөселман, кем мөселман булып уйный гына — аерып алырлык түгел иде. Иң соңыннан ябык кына бер татар егетенә сүз бирделәр.

«Мин, Шәйхетдинов Әхмәт, Чаллыдан, — дип башлады ул үзенең сүзен. — Мөселман, бары тик Аллаһның гына колы. Без Аллаһы Тәгаләнең әмере белән мөселманнарга ярдәмгә килдек. Россия спецорганнары хәзер безнең арага берничә хыянәтчене кертеп, сездә безгә карата шик уятты. Хәзер кемнең хак мөселман икәнен, Аның әмере буенча йөрүен, кемнең шайтанга — Россия органнарына хезмәт итүен бер Аллаһ кына белә. Безнең, татарларның, чеченнар каршында гаебебез юк, без, гомерләребезне дә кызганмыйча, сезнең азатлыгыгыз өчен көрәштек. Арага берничә хыянәтче татарны кертеп, Россия ике мөселман халкын — чеченнар белән татарларны үзара дошманлаштырырга уйлый, шуны аңлагыз. Бу берничә татарның хыянәте аркасында бөтен татар милләтенең йөзенә сатлык дигән кара тап ягылмасын иде. Татарлар да, сезнең кебек үк, бәйсезлек өчен көрәшәләр, дин өчен көрәшәләр, кяфер империясенә каршы көрәшәләр... Аерым татарларның хыянәте өчен безгә гомеребез белән түләргә, хак мөселман икәнебезне сугыш кырында исбатларга мөмкинлек бирегез».

Кинокадрлар шунда бетте. Алып баручы диктор кабат телгә килде.

«Бездә булган мәгълүматлар буенча, — дип дәвам итте ул, — чеченнар татарларның барысын да атканнар. Алар хәтта үзләренә ярдәмгә дип килгән уналты-унҗиде яшьлек татар егетләрен дә кызганып тормаганнар. Бу ерткычларга ярдәмгә килергә кирәк идеме — хәзер Татарстан мөселманнары инде яхшылап уйларлар...»

Әнә шулай акыл өйрәтеп куйганнан соң, диктор теманы дәвам итеп, тагы бер сюжет-өзек карарга тәкъдим итте.

«Бу көннәрдә безгә шушы канлы вакыйгаларның шаһиты булган һәм Россия спецорганнарына зур ярдәм күрсәткән татар егете белән очрашырга туры килде», — дип дәвам итте диктор. Һәм экранда... Хәйдәр күренде.

Бу — берничә көн элек Мәскәүдә төшереп алган кадрлар иде. Диктор тагы сөйли башлады: «Бу татар сугышчысы башта чечен мөселманнары арасына махсус җибәрелеп, Россия өчен кыйммәтле мәгълүматлар туплый, аннан ОМОН составында, кулына корал тотып, Чечняны ислам террористларыннан чистартуда катнаша, беркадәр вакыт чеченнарда әсирлектә дә була. Ул — чеченнарның утыз сигез татар егетен атуларына бердәнбер шаһит. Бүгенге көндә бу татар егете туган шәһәренә кайтарылды. Әмма чечен һәм татар экстремистлары аны хыянәттә гаеплиләр, юк итәргә планлаштыралар, шәһәрдә террор оештырулар белән яныйлар. Бу көннәрдә егет яшәгән йорт органнар тарафыннан махсус рәвештә саклана. Шәһәр тыныч йоклый ала...»

Мәскәүдән хәбәрләр бетте...

Фабарисов белән Хәйдәр, шашынган кебек, бер-берләренә карап каттылар. «Нигә?!» Икесенең дә башында бер генә сорау иде. Нигә Мәскәү бу кадрларны күрсәтергә уйлаган? Фабарисов белә — ФСБ бик сирәк очракта гына үз кешеләрен халыкка күрсәтә. Ә монда барысы да шәрран ачык — чәйнәп диярлек салынды — татарларның мөселман булып чеченнар арасында йөрүләре дә, аларның исемнәре дә, менә бу сарыкның — Хәйдәрнең Чечняда нишләп йөрүләре дә... Әмма иң сәере һәм хәвефлесе шунда — нииндидер булмаган терактларга, һөҗүмнәргә ишарә, имеш, биредә Хәйдәргә яныйлар икән, имеш, аны саклыйлар икән... Юк андый хәл! Аның кайтканын шәһәрдә, Фабарисовтан кала, эт тә белми! Хәтта җәйләр буе бакча саклап яткан анасы да! Тикмәгә генә түгел бу куертулар, тикмәгә генә түгел!

Фабарисов, борчылып һәм ярсып, ишекле-түрле йөри башлады. Ул тилмереп Мәскәүдән бер-бер хәбәр көтә иде. Алар, һичшиксез, шалтыратырга, бу мәсьәләгә ачыклык кертергә тиешләр иде. Әмма Мәскәү дәшмәде.

Хәйдәр исә барлык сорауларына да җавап тапты. Бу җавап аңа үлем карары булып яңгырады. Ул Чечняга махсус җибәрелгән булган икән — башта да, соңыннан да... Аннан файдаланганнар... Димәк, утыз сигез татар егетенең үлемендә аның да гаебе бар! Хәзер дә аны нәрсәгәдер файдаланырга тырышалар. Нииндидер янаулар, саклаулар турында сөйлиләр. Юк бит андый нәрсә, юк, бу шәһәрдә Хәйдәрнең барлыгын белүче дә юк. Менә шушы карт шымчыдан кала... Димәк, ул барысын да алдан белгән, оештырган, Хәйдәрне дә, башка татар егетләрен дә шушы үлем уенында файдаланган? Нәрсә өчен, нигә, нинди хакы бар аның моңа?

Ул бүлмә буенча арлы-бирле чабулаган Фабарисовка ка-

рады. Хәйдәрнең башында бер фикер туып килә иде инде. Ләйлә аны сатлыкҗан дип уйлап, төн уртасында чыгып китте. Әмма Хәйдәрдән, бернәрсә аңламаган яп-яшь малайдан, сатлыкҗан ясаучы менә шушы кеше — Габарисов бит! Имеш, әтисен төрмәдән чыгара, әнисен эшкә урнаштыра, аның үзен укырга кертә, кеше итә! Алар әнисе белән аңа Ходайга караган кебек карыйлар иде бит! Ә ул иблис булып чыкты! Хәйдәрнең җанын, иманын сатып алучы, башын ашаучы иблис булып чыкты! Һәм тагы Хәйдәр кебек күпме беркатлы, ятим, мохтаҗ кешеләрнең башын ашарга мөмкин бу кеше! Аның бу йорттан исән чыгып китәргә хакы юк!

Мәскәү дәшмәде... Габарисовның шомлануы, куркуы артканнан-арта барды. Ник дәшми бу Мәскәү?! Ник бу йортка китерделәр Габарисовны, ник китмәскә куштылар? Нинди булмаган терактлар турында сүз куерта Мәскәү?

Габарисов чабулаган җирендә сөрлегеп китте. Аннан чүгеп куйды. Башыннан алып аяк бармакларына кадәр меңләгән энә чәнчеп үтте. Габарисовның аңына барып җитте — Мәскәү нәрсәдер әзерли иде! Чечняда түгел, нәкъ менә Татарстанда, менә бу шәһәрдә... Менә бу йортта Мәскәү нәрсәдер әзерли иде! Карт шакал моны бөтен күзәнәкләре, кан тамырлары белән тойды — бу йортта бүген нәрсәдер булачак иде! Ул йөгереп тәрәзә янына килде, балконны ачып аска карады. Аста, нәкъ подъезд ишеге төбенә, зур йөк машинасы китереп куйганнар иде. Шәүлә кебек шикле кешеләр машинадан йорт ягына таба нәрсәдер ташыйлар. Бу кешеләр, ничек күренсәләр, шулай тиз генә юкка да чыктылар, йөк машинасы каралып, үз урынында утырып калды...

Йортта үлем тынлыгы урнашты. Инде Габарисовка Мәскәүдән бернинди шалтырату-хәбәр кирәкми иде — ул барысын да аңлады. Ләкин аңламады — нигә аны?! Нигә аны да юлдан алып ташларга булганнар? Күп белгән өченме, бу эшне үз куллары белән оештырган өченме, аның кадрларының чеченнар кулына төшеп ачылулары өченме? Ни өчен Габарисовны әйләнеп үтеп, Габарисовның үзен дә корбан итеп, Мәскәү бу эшкә барырга булган? Димәк, аларның монда берсенә дә ышанмыйлар, аларны бары тик файдаланганнар гына — бер-берләренә каршы, чеченнарга каршы, мөселманнарга каршы...

Бу уйлар Габарисов башыннан яшен тизлегендә үтеп киттеләр. Ул бары хәзер генә үзенең нинди канлы капкынга килеп кабуын аңлады. Ул Мәскәүдәге, Буйнак, Волгодон шәһәрләрендәге шартлатуларның органнар эше икәнен белә иде,

әмма аның үзен дә менә шундый үлемгә хөкем итәрләр дип, ул көтмәгән иде. Чыннан да, шартлау була калса, соңыннан барысын да чечен террористларына, мөселман экстремистларына сылтаячаклар — шәһәрдә ваххабилар бар дип, Фабарисов үзе күпме хәбәрләр биреп ятты. Барысын да аларга ягачаклар. Шәһәрдәге мөселманнар кулга алыначак, төрмәләргә ыргытылачак, мәдрәсәләр ябылачак. Бу эшләрне эшләр өчен аларга инде Фабарисовның кирәге юк, артык күп белүе белән, татар булуы белән ул аларга комачау гына итәргә мөмкин иде... Һәм менә алар Фабарисовны да юлдан алып ташларга булганнар.

Әмма Фабарисовның үләсе килми иде. Ул, соңгы көчен җыеп, ишеккә ыргылды. Өлгерергә, Мәскәүдән хәбәр көтеп ятмаска, бу йортның көле күккә очканчы, ничек тә чыгып, качып өлгерергә кирәк иде...

Ләкин Фабарисовның юлында, кыя булып, Хәйдәр басып тора иде... Ул бер кулы белән Фабарисовны бугазыннан эләктереп алды, икенче кулы белән аның кулларын артка каерып тотты. Фабарисов мондый хәлне көтмәгән иде, ул хәтта кесәсендәге коралына да үрелә алмыйча калды, Хәйдәр аны сөйрәп диярлек балконга алып чыкты. Фабарисов нидер әйтергә теләп, хырылдады, әмма әйтә алмады. Хәйдәр аны җан ачуы белән бөтереп алып өскә күтәрде дә, балкон тәрәзәсеннән аска тотып атты. Фабарисовның үлем ачысы белән акырган тавышын җир җимергеч көчле шартлау басып китте... Фабарисовның гәүдәсе аска төшеп җитә алмады, шартлау дулкыны аны яңадан өскә бәрде, утлы өермә аны җир белән күк арасында бөтереп йөртә башлады. Аның бу дөньяда күргән соңгы сурәте — Мәрьямбануның ватык тәрәзәләреннән җилфердәп чыккан ап-ак пәрдәләр булды... Ул шуларга тотынып булса да, исән калырга, котылырга теләде, әмма аның бөтен тәнен ут ялкыны чорнап алган иде инде. Аның кычкыра-кычкыра януын беркем дә ишетмәде, чөнки бөтен йорт дөрләп яна, җир белән күк арасында бәргәләнә иде...

***...Үрмәкүч корбанына агулы капшавычын батыра алмыйча калды, эссе дулкын аны башта һавага алып чөйде, аннан, җир белән күк арасында бөтереп йөртте дә, ябышкак пәрәвез җәтмәсенә китереп сылады. Үрмәкүчнең муены аяк астына килде, корбанына батырырга дип әзерләгән агулы капшавычлары, ботарланып, үз тәненә батып керде. Агу шул мизгелдә үк бөтен гәүдәсенә таралып, үрмәкүчне эчтән ашый, җимерә башлады. Үрмәкүч, бу афәттән коты-***

***лырга теләп, бәргәләнде, әмма бәргәләнгән саен лайлалы пәрәвез җепләренә ныграк урала барды. Ул бу тоткынлыктан котылу юклыгын аңлады — үрмәкүч үз җәтмәсенә үзе төшкән иде... Күккә сикергән ялкын телләре бу хәшәрәт бөҗәкне ялмап кына алды, әйтерсең лә ул булмаган да, мәңгелеккә дип, агулы җәтмәләрен кормаган да иде...***

Башта көчле шартлау ишетелде.

Тәрәзәләр-ишекләр каерылып ыргытылды, стеналар дөбердәп җимерелеп төште...

Тимербулат, башын куллары белән каплап, каядыр качарга, ничек тә исән калырга тырышты. Аяк астында идән бушлыкка иңә, шуып китеп бара иде. Ул арада каршы як стена гөрселдәп, бу якка авып төште. Ауган стена астыннан Римманың ачыргаланып кычкыруы, ярдәм сорап ялваруы ишетелде. Әмма аңа ярдәм итәрлек көч дөньяда юк иде. Кайдадыр, хәрабәләр арасында, сузып-сузып Сигнал елый иде. Аннан ул да тынды... Төтен, ком-таш тузаны арасыннан берни эзләп табарлык түгел иде...

Аста тагы көчле шартлау ишетелде. Әйтерсең лә йорт чүгеп куйды, аннан, җан тартышып, тагы өскә ыргылды. Тимербулат, стена урынындагы бушлык аша алга сөрлегеп барып төште... Тузан һәм төтен арасыннан да ул танып алды — бу аның үз өе иде... Идән уртасында, намазлыкта, ап-актан киенгән Мәрьямбану утыра иде...

Тимербулат, соңгы көчен һәм зиһенен туплап, нигә икәнен үзе дә аңламыйча, Мәрьямбану янына ыргылды. Мәрьямбануның куллары инде салкын, гәүдәсе, намазлык өстенә тезләнгән хәлдә, инде суынып, катып калган иде. Ул әйтерсең лә шушы хәлендә йокыга гына киткән, ә йөзендә нурлы елмаю балкый иде...

Тимербулат Мәрьямбануны кулларына күтәреп алды. Соңгы шартлау, соңгы көчле дулкын аларның икесен бергә бөтереп алды да каядыр күкләргә алып менеп китте. Аннан, күкләргә менеп җитә алмыйча, тагы җиргә төшерде. Аннан тагы күтәрде, тагы төшерде... Әйтерсең лә күкләр аларны бергә кабул итәргә теләми иде... Җир үзенә тиешлесен генә көтә иде... Әйтерсең лә аларга инде мәңгелектә дә кавышу, бергә булу язмаган иде... Һәм алар соңгы тапкыр бергәләп тормыш дигән утлы мәхшәрнең үлем туенда катнашалар, үлем алдыннан бәхилләшәләр иде...

***Өстә — зәңгәр күк, аста — кара җир, уртада — кеше иде...***

*Башта күкләр хәрәкәткә килде...*
*Бөек әмер белән саф тезелде...*
*Аннан алар рәт-рәт булып җиргә иңде...*
*Җиһанның Хәтер Китабы телгә килде...*
*Аннан Җир-Су хәрәкәткә килде...*
*Күкләр сораганны — Күккә бирде...*
*Җирдә каласыны — Җиргә бирде...*
*Җиһанның Хәтер Китабы телгә килде:*
*«Тәкъдирегез сезнең шушы», — диде.*

*Өстә — зәңгәр күк, аста — кара җир, уртада — бушлык иде...*

*«Алар, Аллаһ биргән белемне хак юлга кулланмыйча, һәлак булдылар».*

*Коръән, «Үрмәкүч» сүрәсе, 38 нче аять*

# ЭЧТӘЛЕК

Кырык сырт

*3*

Караболак

*192*

Соңгы намаз

*547*

Литературно-художественное издание

*Фаузия Байрамова*
*(Байрамова Фаузия Аухадиевна)*

**СОРОК ВЕРШИН**

Романы

(на татарском языке)

Мөхәррире *Ф.М.Хафизов*
Рәссамы *Р.Р.Әхияров*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *С.Н.Нуриева*
Корректорлары *Л.З.Шиһапова, Г.Г.Гарифуллина, Г.Х.Сундукова*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 28.10.2005. Форматы 84×108 1/32. Офсет кәгазе.
«Peterburg» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 35,28 + форз. 0,21.
Шартлы буяу-оттиск 36,12. Нәшер-хисап табагы 40,49 + форз. 0,36.
Тиражы 3000 д. Заказ А-743.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
ГУП Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

ААҖ «Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.